АЛЕКСАНДР ДЮМА

# ӨЧ МУШКЕТЕР

АЛЕКСАНДР
ДЮМА

# ӨЧ МУШКЕТЕР

Роман

КАЗАН
ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1979

И(Фр)
Д96

ЯХЪЯ ХАЛИТОВ тәрҗемәсе

«Өч мушкетёр» романы — XIX йөздә яшәгән (1802—1870) атаклы француз язучысы Александр Дюманың иң мәшһүр әсәрләреннән берсе. (Соңрак бу роман трилогиянең беренче кисәге булып китә. Икенче кисәге «Егерме ел узгач», өченчесе «Ун ел узгач яки Виконт де Бражелон» дип атала.) Бу мажаралы-тарихи романда XVII гасырның 20 нче елларында Франциядә булган вакыйгалар тасвирлана. Персонажларының байтагы — шул заманда яшәгән чын тарихи шәхесләр (король Людовик XIII, кардинал Ришелье, герцог Бекингэм һәм башкалар). Әмма Дюма тарихи чынлыкны әсәренә төп җирлек итеп кенә ала, шул фонда ул бик оста, мавыктыргыч итеп мажаралы вакыйгалар кора, бу вакыйгаларда үзенең каһарманнары Атос, Портос, Арамис һәм д'Артаньянның көчле, мәкерле дошманнарына каршы көрәшен күрсәтә, ә аларның чын егетләргә хас күркәм сыйфатларын — намуслы, батыр, ир йөрәкле булуларын укучы сокланырлык итеп ачып бирә.

УРТА ҺӘМ ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Д $\frac{70803-256}{М132(03)-79}$ 127—79

© Русчадан тәржемә. Татарстан китап нәшрияты, 1979.

# АВТОРНЫҢ КЕРЕШ СҮЗЕ

Бу кереш сүздә укучыларыбызга сөйлисе хикәябез каһарманнарының, исемнәре «ос» һәм «ис»кә тәмамлана торган булса да, бернинди мифология белән алыш-бирешләре юк икәнлеге әйтелә.

Моннан бер ел чамасы элек, король китапханәсендә Людовик XIV нең тарихын язар өчен материаллар эзләгәндә, мин очраклы рәвештә «Д'Артаньян әфәнде истәлекләре» дигән бер китапка тап булдым. Шул заманның күпчелек әсәрләре шикелле (дөреслекне Бастилия төрмәсенә эләкмәслек итеп кенә әйткән әсәрләр кебек), бу истәлекләр дә Амстердамда, Пьер Руж матбагасында басылган булган. Китапның исеме мине бик кызыксындырды; мин бу истәлекләрне,— әлбәттә, китапханә хезмәткәренең рөхсәте белән,— өйгә алып кайтып, йотылып укырга керештем.

Бик кызыклы бу әсәрне мин биредә тәфсилләп тикшерергә җыенмыйм, үткән заман картиналарына бәя бирә белүче укучыларыма шуның белән танышырга киңәш кенә итәм. Алар бу мемуарлардан оста рәссам кулы белән төшерелгән портретлар табарлар, тиз-тиз генә эшләнгән бу рәсемнәр күбесенчә казарма ишекләренә һәм мәйханә стеналарына ясалган булса да, укучылар барыбер аларда Людовик XIII, Анна Австрияле *, Ришелье, Мазаринины һәм ул замандагы башка сарай әһелләрен күреп таныйлар. Болар Анкетиль әфәнде ** тарихындагы шикелле үк дөрес сурәтләр.

Әмма, билгеле булганча, кайвакыт язучының күңелен күп укучылар күрми торган нәрсәләр кызыксындыра. Мемуарларның әле әйтеп кителгән якларына соклану белән бергә (моңа, һичшиксез, башкалар да сокланырлар), безне моңарчы, мөгаен, беркем дә әһәмият итмәгән башка кайбер яклары таң калдырды.

Д'Артаньян болай дип сөйли: ул беренче тапкыр король мушкетерлары капитаны де Тревиль·әфәнде янына килгәч, шунда өч егетне очраткан. Болар д'Артаньян үзе дә хезмәт итәргә теләгән атаклы полкның гаскәриләре Атос, Портос һәм Арамис икән.

Турысын гына әйткәндә, бу исемнәр безнең колакка бик сәер булып тоелды һәм без аларны кушамат кынадыр дип уйладык, бәлки, д'Артаньян әлеге атаклы кешеләрнең чын исемнәрен әйтергә теләмәгәндер, бәлки, алар ирекле баштанмы, ирексездәнме, яисә мохтаҗлыктанмы дигәндәй, өсләренә гади мушкетер плащы кигән көнне үзләре шул кушаматларны сайлап алганнардыр, дип тә гөман кылдык.

---

* Анна Австрияле — Франция королевасы, Людовик XIII нең хатыны, Австрия короленең сеңлесе.

** Аббат Анкетиль (1723—1806) — берничә томлы Франция тарихының авторы. *(Редакция искәрмәсе.)*

Шуннан соң инде без, бөтен тынгылыгыбызны җуеп, шул заманның әсәрләреннән бездә зур кызыксыну уяткан бу гаҗәеп исемнәрнең нинди дә булса берәр эзен табарга тырыштык.

Шул максат белән без укып чыккан китапларның исемлеге генә дә үзе бер бап булыр иде, ихтимал, бик гыйбрәтле булса да, укучылар өчен әллә ни кызыклы булмас иде. Шуңа күрә укучыларыбызга бары тик шунысын гына әйтеп китәбез: эзләнүебезнең берәр нәтиҗәсе булуыннан өмет өзеп, бу эшне бөтенләй ташларга дип торганда гына без, ниһаять, атаклы һәм галим дустыбыз Полэн Парисның киңәшләренә таянып, in fólio* кулъязма таптык. 4772 нчеме, 4773 нчеме номер белән теркәлгән иде бугай — анысын төгәл генә хәтерләмибез,— ә исеме болай:

«Король Людовик XIII патшалык иткән чорның азагында һәм король Людовик XIV патшалык итә башлаганда Франциядә булган кайбер вакыйгалар турында граф де ла Фер истәлекләре».

Соңгы өметебез булган шушы кулъязманы актарган чакта егерменче биттә Атос исемен, егерме җиденче биттә Портос исемен һәм утыз беренче биттә Арамис исемен очраткач, шатлыгыбызның чиге булмады.

Тарих фәне шулкадәр үсеп киткән бер заманда бөтенләй билгесез кулъязма табу безнең өчен үзе бер могҗиза булып тоелды. Без аны бастырып чыгару өчен тизрәк рөхсәт алырга ашыктык — үз багажыбыз белән Франция академиясенә кабул итмәсәләр (анысы бик ихтимал), нчмасам, кайчан да булса бер кеше багажы белән Язмалар һәм Матур Әдәбият Академиясенә үтеп булмасмы дидек.

Безгә аны басып чыгарырга бик теләп рөхсәт иттеләр,— моны әйтеп китүне бурычыбыз дип саныйбыз һәм, әдәбиятчылар үзләрен бик үк яратып бетермәгән хөкүмәт хакимлеге астында яшиләр дип ялган таратучы яман кешеләрне ачыктан-ачык фаш итү өчен, без үзебезгә рөхсәт бирелгәнлеген шушында тәсдыйк кылып китәбез.

Хәзер без әлеге кулъязманы, тиешле исемен куеп, укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез һәм аның шушы беренче кисәге лаеклы уңышына ирешә алса (моңа без шикләнмибез), озакка сузмыйча икенче кисәген дә бастырып чыгарырга сүз бирәбез.

Баланы кабул итеп алучы кеше аның икенче атасы булып саналганлыктан, хәзергә без укучыдан китапны укыгандагы күңеллелек һәм күңелсезлекләрнең сәбәбен граф де ла Фердан түгел, бәлки бездән эзләвен үтенәбез.

Менә шуны ачыклаганнан соң инде, хикәябезне бәян итүгә керешәбез.

---

* In fólio *(латинча)* — ярты табак күләмендә яки форматта басылган китап яисә журнал. *(Ред. искәрмәсе.)*

# *Беренче кисәк*

## I

## ӘТИ КЕШЕ Д'АРТАНЬЯН ӘФӘНДЕНЕҢ ӨЧ БҮЛӘГЕ

1625 нче ел, апрель аеның беренче дүшәмбесе көнне Мёнг каласы кешеләре («Роза турындагы роман» * ның авторы кайчандыр шушы калада туган булган) шулкадәр дә әсәрләнгәннәр-каушаганнар иде — әйтерсең һугенотлар ** бу шәһәрне икенче Ларошельгә *** әйләндерергә җыеналар иде. Кала кешеләренең беришесе, Олы урамга таба хатын-кызлар йөгерешкәнен күргәч һәм янә дә ишек төпләрендә бала-чага елашуын ишеткәч, тиз-тиз генә гаскәри киемнәрен киделәр, гайрәтлерәк-батыррак күренер өчен кайсы кулына мушкет, кайсы айбалта тотты да «Хөр Тегермәнче» кунакханәсе янына чапты — анда инде, «ни хикмәт бар икән?» — дип әсәренеп, бик күп кеше җыела, шау-гөр килә башлаганнар иде.

Ул заманнарда мондый халык ыгы-зыгысы гадәти бер хәл булган, һәм үз елъязмасына көн саен шундый бер вакыйга теркәми калган берәр шәһәр булдымы икән?! Бай түрәләр бер-бере белән тәпәләшкәннәр, король кардиналга каршы көрәшкән, испаннар король белән сугышканнар. Кайсы астыртын, кайсы ачыктан-ачык барган мондый көрәштән тыш, әле бөтенесенә дә каршы көрәшүче ярлылар һәм һугенотлар, сукбайлар һәм ялчылар да булган. Кала кешеләре карак, сукбай, ялчы-

---

* «Роза турында роман» — урта гасырның атаклы бер поэмасы. Ул Гильом де Лоррис тарафыннан языла башлап, икенче кисәген Жан Клопинель (Мёнгле) иҗат иткән. *(Ред. искәрмәсе.)*.

** Һугенотлар — Франциядә кальвинистлар (протестантлар) дине тарафдарлары. XVI гасырның икенче яртысында — XVII йөзнең башында башлыча король властеның үзәкләштерү политикасыннан риза булмаган дворяннар һәм эре феодалларның бер өлеше һугенотлар булганнар. *(Ред. искәрмәсе.)*.

*** Ларошель — Атлантика океаны буендагы бер шәһәр, һугенотларның төп терәге, 1628 елда, бик озак камап торганнан соң, кардинал Ришелье тарафыннан яулап алына. *(Ред. искәрмәсе.)*.

ларга каршы коралланып чыкканнар, еш кына бай вельможаларга, вакыт-вакыт корольгә каршы да кузгалышканнар, әмма кардинал белән испаннарга каршы корал күтәрмәгәннәр. Әнә шул канга сеңгән гадәт буенча, бая әйтелгән 1625 нче ел апреленең беренче дүшәмбесе көнне кала халкы, шау-шу ишеткәч, герцог Ришелье хезмәтчеләренең сарылы-кызыллы тамгаларына да, ука-чукларына да игътибар итмәстән, «Хөр Тегермәнче» кунакханәсе янына чапты.

Ыгы-зыгының сәбәбе шунда барып җиткәч кенә аңлашылды.

Сәбәпчесе яшь кенә бер егет иде... Без аның төс-кыяфәтен дә сурәтләп карыйк: өстенә рыцарь киемен — көбәсен кимәгән, чапрагын япмаган, бары тик йон көрти генә кигән унсигез яшьлек дон Кихотны күз алдыгызга китерегез. Көртиенең инде төсе уңып куе зәңгәрдән кызгылт-сыек зәңгәргә әйләнгән. Карасу тутлы озынча йөз; яңак калкымнары чыгып тора — моныСЫ хәйләкәрлек билгесе; казна сеңерләре бик таза — бусы, башларында берет булмаса да, Гасконь * кешеләрен бүтәннәрдән аерып тора торган бер сыйфат,— безнең егет исә башына берет кигән, аңа каурый сыман бер нәрсә дә кадап куйган иде; карашы ачык, акыллы; борыны бөкрерәк булса да нәфис кенә; үсмер егет дияргә — буе зуррак, җитлеккән ир дияр иде — тәбәнәгрәк. Җәяү атлаганда балтырларына бәрелә, ат өстендә барганда атының ялын тузгыткалый торган, күн портупеяга аскан озын саплы кылычы булмаса, тәҗрибәсезрәк кеше аны сәяхәткә чыгып киткән бер фермер малае дип уйлар иде.

Безнең егетнең кеше күзе төшәрлек күрекле генә аты да бар әле — кызгылт-сары йонлы, койрыгында кыллары коелып беткән, бәкәлләре шешкән унөч-ундүрт яшьлек Беарн ** алашасы анысы. Бу ат борынын тездән түбән салындырып юртса да (бу рәвешле барганда хуҗасына авызлыкны тарткалыйсы булмый), көненә сигез лье чамасы юл уза иде әле. Бәхетсезлегенә каршы, алашаның шыксыз кыяфәте һәм сәер төсе аның әлеге сыйфатын томалап киткән, шуңа күрә бу Беарн алашасының моннан чирек сәгать кенә элек Божанси капкасыннан Мёнг каласына килеп керүе, ул елларда күп кеше ат дигән малның рәтен яхшы белгәнлектән, җайдакның үзенә дә күләгә төшерерлек ямьсез бер тәэсир калдырган иде.

Яшь д'Артаньян (яңа Россинантка атланган бу яңа дон Кихотның исеме шулай иде), атта бик шәп йөри торган егет булуына карамастан, мондый котсыз алаша белән кеше күзенә бик көлке күренәчәген үзе дә сизгән һәм моңа бик кимсенгәнхурланган да иде. Шуңа күрә ул әтисе кулыннан бу бүләкне

---

* Гасконь — Франциянең көньягындагы бер өлкә (провинция). Гасконь дворяннары гадәттә король гвардиясендә хезмәт иткәннәр.

** Беарн — Франциянең көньягында, Пиреней тавы итәгендәге бер өлкә (провинция).

алган чагында ирексездән көрсенеп-авыр сулап куйды. Мондый атның бәһасе күп дигәндә егерме ливр икәнлеген егет белә иде. Аның каруы бу бүләкне тапшырган вакытта атасы әйткән киңәшләр алтын бәһасенә торырлык иде.

Гасконь дворяны Һенрих IV * дә гомере буена оныта-ташлый алмаган саф Беарн акценты белән әйтте:

— Углым! — диде.— Шушы аргамак атагыз йортында моннан унөч ел элек дөньяга килгән иде, шул гомере эчендә ул безгә бик тугры хезмәт итте, шуның өчен дә сез аны яратырга тиешсез. Нинди хәлләргә төшсәгез дә, сатмагыз аны, кадер-хөрмәт белән тынычлыкта картайганчы яшәп үлсен. Әгәр дә мәгәр сезгә шушы аргамакка атланып сәфәр чыгып китәргә туры килә икән, карт хезмәтчене кызганган кебек кызганыгыз аны, җәберләмәгез. Король сараенда,— дип сүзендә дәвам итте өлкән д'Артаньян,— әгәр анда сезне кабул итсәләр,— нәселегезнең бик борыннан килүе сезгә нәкъ шундый хокук бирә,— үзегез һәм якыннарыгыз хакына дворян дигән намыгызның абруен сакларга тырышыгыз — сезнең бабаларыгыз биш гасыр буена шул зур намга лаек булып килгәннәр. «Якыннарыгыз» дигәндә мин сезнең туганнарыгыз белән дусларыгызны күздә тотам. Король белән кардиналдан гайре берәүгә дә баш бирмәгез. Безнең заманда дворян фәкать батыр йөрәге белән генә — ишетәсезме: батыр йөрәге белән генә — үзенә юл яра ала. Бер генә мизгелгә куркып-каушап калсагыз да, тәкъдирегез нәкъ шул мизгелдә китереп биргән бәхетне кулдан ычкындыруыгыз ихтимал. Сез яшьсез һәм батыр йөрәкле булырга тиешлегегезнең ике сәбәбе бар: беренчедән, сез Гасконь кешесе, аннары, өстәвенә, сез минем улым. Очраклы хәлләргә әлегүдән бер дә курыкмагыз һәм маҗаралар эзләгез. Мин сезгә кылыч сугышына өйрәнергә мөмкинлек бирдем. Сезнең ботларыгыз тимер кебек таза, кулларыгыз корыч кебек нык. Сәбәп чыгу белән, шундук сугышка ташланыгыз, дуэльдә дә сугышыгыз,— дуэльгә чакыру хәзер тыелган, шулай булгач, димәк, алай сугышыр өчен бермә-бер батыр йөрәкле булырга кирәк. Мин сезгә, углым, нибарысы унбиш экю акча, аргамагымны һәм менә әле үзегез ишеткән киңәшләремне генә биреп җибәрә алам. Әнкәгез, боларга өстәп, чегән хатыныннан алып калган ниндидер бәлзәм рецепты бирер. Бик сихәтле бәлзәм икән — йөрәк ярасыннан гайре бөтен җәрәхәтне дәвалый. Әнә шуларның барысының файдасын күреп, бәхет-шатлык эчендә озын гомер кичерегез... Шуларга өстәп тагы бер генә нәрсә әйтәсем калды: сиңа үрнәк булырдай кешене әйтәсем килә — үземне димим, чөнки минем беркайчан да король сараенда

---

* Һенрих IV Бурбон — Франция короле (1553—1610). Тәхеткә менгәнче һугенотларның юлбашчысы була. Соңрак политик сәбәпләр аркасында католиклыкка күчә. 1598 елда ул Нант эдикты (указы) чыгара. Бу указ белән һугенотларга дин тоту иреге һәм беркадәр политик бәйсезлек бирелә.

хезмәт иткәнем булмады, мин фәкать ирекле булып динебез өчен кузгалган сугышларга гына катнаштым. Кайчандыр минем күршем булып яшәгән де Тревиль җәнапларын күздә тотам мин. Бала чагында ул королебез Людовик Уnөченче* белән бергә уйнап үскән иде — ходай сәламәтлек бирсен үзенә! Кайчагында уйный-уйный сугышып китәләр дә корольгә шактый эләккәләп тә ала торган иде. Де Тревиль җәнапларының йодрыгы үзенә карата корольдә зур ихтирам һәм дуслык тойгылары уятты. Соңрак инде, беренче тапкыр Парижга баргач, де Тревиль җәнаплары башкалар белән биш тапкыр сугышкан, король мәрхүм үлгәннән соң, яшь король балигъ булып җиткәнче — сугыш һәм походларга катнашуын санамаганда — җиде тапкыр сугышкан, инде яшь король балигъ булган вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр — йөз тапкыр сугышкандыр! Ул хәзер дә, әллә ниткән эдикт, боерык, карарларга карамастан, мушкетерлар башлыгы, ягъни Цезарь легионы капитаны,— бу легионны король бик яклый, ә кардинал шүрли аннан. Де Тревиль җәнапларының исә,— бөтен кешегә мәгълүм,— бернигә дә исе китми. Моның өстенә, де Тревиль җәнаплары елына ун мең экю акча ала. Димәк ки, ул шактый зур түрә. Ул да эшкә нәкъ сезнең шикелле башлаган. Менә шушы хат белән аның катына барыгыз, аңардан үрнәк алып, аның шикелле үк эшкә керешегез.

Шулай дигәннән соң, өлкән д'Артаньян әфәнде улының кулына үз кылычын тоттырды да, аталарча ике битеннән дә үбеп, малаена фатыйха бирде.

Әтисе бүлмәсеннән чыгып барганда, егет теге бәлзәм рецептын тотып көтеп торган әнисен күрде (бая әтисе әйткән киңәшләргә караганда, бу бәлзәмне егеткә бик еш кулланырга туры килер әле). Мондагы саубуллашу әтисе белән саубуллашуга караганда озаграк һәм хислерәк булды; алай булуы, әлбәттә, әти кеше бердәнбер баласын яратмаганнан түгел, моның сәбәбе икенче иде: д'Артаньян әфәнде — ир кеше, шуңа күрә ул күңел нечкәрүне ир кешегә килешми дип саный, д'Артаньян ханым исә хатын-кыз һәм ана кеше иде. Улы белән аерылышкан чакта ул бик каты елады. Шуны да әйтик: кече д'Артаньян әфәнде булачак мушкетерлыгына лаек рәвештә никадәр түзем булырга тырышмасын, барыбер хискә бирелеп китеп, байтак яшь койды, ярый әле күз яшьләренең яртысын булса да, әнисенә күрсәтмичә, яшереп кала алды.

Шул ук көнне егет, әйткәнебезчә, әтисеннән алган өч бүләк белән — унбиш экю акча, кызгылт-сары аргамак һәм де Тревиль әфәнде исеменә язылган хаты белән — юлга чыгып китте. Әтисе биргән акыл-киңәшләр, әлбәттә, бүләк исәбенә керми иде.

---

* Людовик XIII — француз короле (1601—1643), барлык мәсьәләләрдә үзенең беренче министры кардинал Ришелье йогынтысында эш иткән.

Күңеленә әтисенең әнә шул акыл-киңәшләрен дә салып куйгач, д'Артаньян бөтенләй — тәне һәм җаны белән дә — без бая искә алган Сервантес каһарманына охшап калды. Дон Кихот күзенә җил тегермәннәре гаҗәеп зур кешеләр булып, сарык көтүе исә гаскәр булып күренгән. Д'Артаньян исә каршысына очраган кешенең елмаеп үзенә күз салуын күргән саен: «Мине кимсетеп, мыскыл итеп көлә бу кеше»,— дип уйлады. Шуңа күрә Тарбтан Мёнгка килеп җиткәнче ул йодрыгын гел йомарлап барды, көненә ун тапкырлап кылычына ябышты. Шулай да ул йодрыгы белән берәүнең дә яңак төбенә утыртмады, кылычын да кынысыннан суырып чыгармады. Дөрес анысы, котсыз карт алашаны күргәч, авыз ерып калучылар булмады түгел, әмма алашаның кабыргаларына бәрелгәләп барган бик дәү кылычны һәм аннан өстәрәк ачу-ярсу белән янган күзләрне күргәч, узгынчылар шундук елмаймас булдылар, тыела алмаганнары исә, борынгы маска шикелле, йөзләренең ярты ягы белән генә елмаерга тырыштылар. Әнә шул рәвешчә, д'Артаньян, мәһабәт бер кыяфәт белән, ачу-ярсуы кайнап-ташып чыгарга торган хәлдә, Мёнг каласына килеп җитте.

Бу калада ул «Хөр Тегермәнче» дигән кунакханәнең капкасы төбендә, гадәттә килгән кунакның өзәнгесен тотып торучы хуҗа, хезмәтче яисә ат караучылар ярдәменнән башка гына аргамагыннан төшкән чагында, икенче катның ачык тәрәзәсеннән озын буйлы, тәкәббер-эре кыяфәтле, төксе генә чырайлы бер дворянны күрде. Бу дворян үзенең ике юлдашына нәрсәдер сөйли, тегеләре ихтирамлы бер төс белән аны тыңлап торалар иде шикелле.

Д'Артаньян, гадәтенчә, «болар минем турыда сөйләшәләр икән», дип уйлады һәм, бөтен дикъкатен туплап, тегеләрнең нәрсә сөйләшкәнен тыңларга кереште. Бу юлы инде егет ялгышмады диярлек, ялгышса да бик аз ялгышкандыр: тегеләр егетнең үзе турында түгел, аның аты турында сөйләшәләр иде. Әлеге ят кеше аның атының күркәм сыйфатларын атап сөйли иде, күрәсең,— әйткәнемчә, аны зур ихтирам белән тыңлап торучы ике кеше тегенең һәр сүзе саен эчләре катып көләргә керешә иде. Чак кына авыз ерып көлемсерәү дә безнең каһарманыбызның ачуы ташуга сәбәп булуын истә тотсак, бу рәвешчә көлүнең егеткә ничек тәэсир иткәнлеген күз алдына китерүе кыен булмастыр, шәт.

Д'Артаньянның, иң элек, үзеннән көлүче бу адәмне әйбәтләбрәк карыйсы-күрәсе килде. Ят кешегә горур карашын төбәде. Кырык яшьләр чамасындагы, үткен кара күзле, ак чырайлы, дәү генә борынлы, бик әйбәтләп төзәтелгән ыспай гына мыеклы бер кеше иде ул. Өстендә — камзул, шәмәхә төстәге шнурлы чалбар, эчке күлмәге күренеп торган гадәти ерыгыннан башка, чалбарында андый-мондый өстәмә бизәкләр юк иде. Чалбар белән камзулы, яңа булсалар да, сандыкта озак яткан юл киеме шикелле таушалып, бөгәрләнеп беткән иде.

Д'Артаньян боларның барысын бик нечкә күзәтә белүче кеше җитезлеге белән берьюлы күреп алды,— егетнең тормышында бу адәмнең зур роль уйнаячагын сизенгән инстинкт тойгысы да ярдәм иткәндер, бәлки, моңа.

Шул рәвешчә, д'Артаньян шәмәхә камзуллыга күзен төбәп карап торганда, әлеге кеше Беарн аргамагы исеменә үзенең иң усал, иң тапкыр сүзен әйтеп куйды. Янындагы ике кеше эчләре катып көләргә керештеләр һәм шул вакыт сөйләп торучының да йөзендә, гадәтендә булмаганча, сыек кына бер көлемсерәү шәүләсе чагылып китте. Бу юлы инде бернинди шик-шөбһә калмады: болар д'Артаньянны күрә торып хурлыйлар, мыскыл итәләр иде.

Башкача булуы мөмкин түгел дип, егет беретын батырыбрак киде дә, король сараендагы манерларга охшатырга тырышып (ул аларны Гасконьга килгән бай сәяхәтчеләрдән күреп калган иде), бер кулы белән кылыч сабын тотты, икенчесе белән бөеренә таянып, алга атлады. Бәхетсезлегенә каршы, теге кешегә якынайган саен егетнең ачу-ярсуы аңын томалый башлады, шуңа күрә ул, дуэльгә чакыру сүзләрен эре һәм горур бер кыяфәт белән белдерәсе урында, кулын бик каты селтәнгәләп, берничә тупас сүз генә әйтә алды.

— Әй, әфәндем! Әйе, тәрәзә кырыена посып торучы, сезгә эндәшәм! Рәхим итеп әйтегез әле: нәрсәдән көләсез? Бәлкем, барыбыз бергә көләрбез! — дип кычкырды.

Бай мөсафир карашын әкрен генә аттан алып җайдакның үзенә күчерде. Бу кадәр сәер шелтә сүзләренең үзенә төбәп әйтелгәнен ул беравык аңышмый торды шикелле. Аңлап алгач инде, кашларын җыера төште һәм, шактый сүзсез торганнан соң гына, әйтеп бетергесез һөҗү* һәм тәкәбберлек белән җавап кайтарды:

— Мин бит сезнең белән сөйләшмим, хөрмәтле әфәндем! — диде.

— Аның каруы мин сезнең белән сөйләшәм! — дип кычкырды егет — бу кешенең бер үк вакытта оятсыз да, нәзакәтле, әдәпле дә була белүе һәм кимсетеп-түбәнсетеп тә сөйләшүе д'Артаньянның ачуын китерде.

Ят кеше беравык егеттән күзен алмый карап торды, аннары тәрәзә яныннан китеп, ашыкмый гына кунакханәдән чыкты да д'Артаньяннан бер-ике адым чамасында гына нәкъ атның каршысына килеп туктады. Аның мыскыл иткән кебек сабыр гына басып торуы тәрәзә янында калган әңгәмәдәшләренә тагы да кызыграк тоелды.

Әлеге кеше үзенә таба килә башлагач, д'Артаньян кылычын бер фут озынлыгында кынысыннан суырып чыгарды.

— Бу ат чыннан да сап-сары икән, дөресрәге — кайчандыр сап-сары булган,— диде әлеге адәм, тәрәзә катындагы әңгәмә-

* Һөҗү — ирония.

дәшләренә мөрәҗәгать итеп. Шул ук вакытта үзе белән әңгәмәдәшләре арасында ачуыннан бузарынып Гасконь егете басып торуына бер дә исе дә китмәгән булды. Моңарчы, атлардан бигрәк, үсемлекләр дөньясына хас иде бу төс.

— Хуҗасыннан көләргә йөрәге җитмәгән кеше генә аның атыннан көлә! — дип ярсып җавап кайтарды егет.

— Мин бик сирәк көләм, әфәндем,— диде әлеге кеше.— Сез моны чыраема карап та сизә аласыз. Әмма мин үзем теләгәндә көләргә хакым бар дип ышанып яшим.

— Ә менә мин үзем теләмәгәндә беркемнән дә үземнән көләргә ирек бирмим! — диде д'Артаньян.

— Чынлапмы, әфәндем? — дип кайтарып сорады әлеге кеше тагы да тынычрак тавыш белән.— Һе, сезнең сүздә дә хаклык юк түгел.

Шулай дигәч, ул үкчәләре белән кырт кына борылды да кунакханә капкасына таба китте. Д'Артаньян бая капка төбенә килеп туктаганда анда иярләгән бер ат барлыгын искәреп калган иде.

Әмма д'Артаньян үзен мыскыл иткән кешеләрне алай ансат кына җибәрә торган егет түгел иде шул. Ул кылычын кынысыннан бөтенләй суырып чыгарды да үзен кимсеткән әлеге кеше артыннан ташланып:

— Борылыгыз, әфәндем, борылыгыз, югыйсә минем сезгә арттан китереп кадавым ихтимал! — дип кычкырды.

Ят кеше тагын кырт кына борылды һәм егеткә гаҗәпсенгән дә, шул ук вакытта кимсеткән дә бер төс белән күзен төбәп:

— Сез миңа кадамакчы буласызмы? Ни сөйлисез, ни сөйлисез, сөеклем, акылыгыздан яздыгызмы әллә?! — диде.

Һәм шуның артыннан ук, үз алдына гына сөйләнгәндәй, әкренрәк тавыш белән әйтеп куйды:

— Ах, хәерсез! Үз мушкетерларының сафын арттырыр өчен бөтен җирдән батыр егетләр эзләгән галиҗәнап өчен бик зур табыш бит бу...

Ул сүзен әйтеп бетергәнче үк д'Артаньян, ярсып, кылычы белән аңа таба ташланды — әлеге кеше вакытында читкәрәк тайпылып өлгермәсә, аның бу шаяртуы, ихтимал, гомерендә соңгы шаяртуы булган булыр иде. Ят кеше, эшнең җитдигә китүен төшенеп кылычын суырып чыгарды да, дошманына таба сузыла төшеп, чын-чыннан каршы торырга хәзерләнде. Ләкин шул чагында аның теге ике гәптәше, трактирчы белән бергә, кулларына таяк, көрәк, камин кыскычы тотып д'Артаньянга ташландылар да өчәүләшеп аны тукмарга керештеләр. Көтелмәгән бу һөҗүм хәлне бөтенләй үзгәртеп җибәрде, һәм д'Артаньянның дошманы, егетнең таяк, көрәк, кыскычларга каршы түше белән борылуыннан файдаланып, кылычын тыныч кына кынысына салып куйды. Хәзер ул кара-каршы сугышка катнашучы булудан бигрәк шаһит хәлендә калды һәм бу ролен үзенә хас сабырлык белән башкарды. Шулай да:

— Шайтан алсын бу Гасконь кешеләрен! Сез аны кызгылт-сары аргамагына тизрәк атландырыгыз да олактырыгыз моннан,— дип мыгырданды үзе.

Д'Артаньян, өч дошманына таба карап баскан хәлдә сугыша-сугыша, тегенең сүзенә каршы:

— Сине үтермичә олакмыйм әле мин, куян йөрәк! — дип кычкырды.

— Гасконь мактанчыгы! — дип мыгырданды ят кеше.— Ант әгәр, шыр җүләрләр бу Гасконь кешеләре! Ярый алайса, үзе шуны тели икән — әйбәтләп тукмагыз. Хәлдән тайгач, туктар әле.

Әмма ят кеше бик үзсүзле бер егет белән эш иткәнен белми иде әле. Рәхим-шәфкать сорый торган егет түгел иде шул д'Артаньян. Шуңа күрә сугыш әле тагын берничә секунд дәвам итте. Ахырда Гасконь егетенең хәле бетте, таякка бәрелеп сынган кылычы кулыннан төшеп китте. Шуннан соң аның маңгаена китереп суктылар. Маңгаеннан шыбырдап кан ага-ага, д'Артаньян аңын җуя язып җиргә ауды.

Нәкъ шул вакытны шушы хәл булган төшкә төрле яктан чабышып халык җыела башлаган иде. Кунакханә хуҗасы, кирәкмәгән сүз булудан куркып, хезмәтчеләре булышлыгы белән егетне кухняга алып китте, шунда аңа бераз ярдәм күрсәттеләр.

Теге кеше исә тәрәзә янындагы элекке урынына кайтып, өнәмәгән бер төс белән, җыелган халыкка карап тора башлады — бирегә кеше җыелуы аңа бер дә ошамый иде, күрәсең.

Ул ишек ачылган тавышка борылып карады да аның кәефен белешергә кергән трактирчыдан:

— Я, теге батырның хәле ничек? — дип сорады.

— Сез галиҗәнаплар сау-сәламәтме? — дип сорады трактирчы.

— Сау-сәламәт, сөекле хуҗам. Минем әлеге егетнең хәлен беләсем килә иде.

— Хәле бераз яхшыра башлады. Бөтенләй аңын җуйган иде югыйсә,— диде хуҗа.

— Чынлапмы? — диде теге кеше.

— Анарчы әле ул, актык көчен җыеп, сезгә эндәште, сүгенде-тиргәнде, сугышуны таләп итте.

— Чын җен икән! — дип куйды теге кеше.

— Түгел, түгел, мөхтәрәм әфәнде,— диде кунакханә хуҗасы, мыскыллы бер төс белән авызын кыйшайтып.— Ул һушсыз яткан арада тентедек без аны. Төенчегендә нибары бер күлмәге, янчыгында унбер экю акчасы бар иде. Әмма, шуңа карамастан, һушсыз ятса да, үзе һаман сөйләнде: бу хәл Парижда булса, шундук тәүбәгезне әйттергән булыр идем, ярар, соңрак әйттерермен мин аны, ди.

— Алайса, ул төс-бит алмаштырган принцтыр,— дип салкын гына әйтеп куйды теге кеше.

— Сезгә моны белеп торыгыз дип искәртеп куюым иде,— диде хуҗа.

— Безне суккән чагында берәр кешенең исемен телгә алмадымы?

— Әйе, әйе, телгә алды! Кулы белән кесәсенә суккалап, берничә тапкыр әйтте: «Карап карарбыз, менә де Тревиль җәнаплары үз химаясендәге кешене мыскыл иткәнлекләрен белгәч нәрсә әйтер икән»,— диде.

— Де Тревиль җәнаплары? — диде әлеге кеше сагая төшеп.— Кесәсенә суккалап, де Тревиль җәнапларының исемен телгә алдымы?.. Я, ничек соң, хөрмәтле хуҗа? Минемчә, егетебез һушсыз яткан чагында сез әлеге кесәне дә тикшерү форсатын ычкындырмагансыздыр дип беләм. Ул кесәдәниләр бар иде соң?

— Мушкетерлар капитаны де Тревиль җәнаплары исеменә атап язылган хат бар иде.

— Шулай укмыни?

— Нәкъ шулай, нәкъ әле генә сез мөхтәрәм әфәндегә әйткәнемчә.

Әллә ни күңел сизгерлеге булмаган кунакханә хуҗасы әлеге кешенен бу сүзне ишеткәч чырае бозылып китүен абайламады. Ят кеше тәрәзә янагына сөялеп торган җиреннән кузгалып китте дә борчылып кашларын җыерды.

— Ах, иблис! — диде ул тешен кысып.— Минем арттан шушы Гасконь егетен Тревиль җибәрде микәнни? Артык яшь бит! Әмма кылыч белән кадау — кадаучысы ничә яшьтә булса да — барыбер кылыч белән кадау инде. Малай-шалайдан исә мин азрак шикләнәм. Кайчагында кечкенә генә бер киртә дә зур максатка ирешүдә комачау булып төшә.

Ят кеше беравык уйга калып торды.

— Карагыз әле, хуҗа! — диде аннары.— Сез мине шул тилемсәдән коткару мәшәкатен өстегезгә алмассызмы? Аны үтерергә минем вөҗданым кушмый, мәгәр ул...— чыраена салкын бер рәхимсезлек галәмәтләре чыкты,— мәгәр ул миңа бик комачау итә. Кайда ул хәзер?

— Хатыным бүлмәсендә, икенче катта. Аның яраларын бәйлиләр.

— Әйберләре белән сумкасы үзе янындамы? Камзулын салмаган идеме?

— Камзулы да, сумкасы да аста, кухняда калды. Әгәр ул тиле егет сезгә комачау итә икән...

— Әлбәттә, комачау итә. Сезнең кунакханәдә ул гауга чыгарып, җүнле кешеләргә борчу тудыра. Сез үз бүлмәгезгә кайтып, миңа счет хәзерләгез дә минем хезмәтчемә әйтеп куегыз.

— Ничек инде ул алай? Сез, мөхтәрәм әфәнде, бездән китәсез дәмени?

— Минем китүем моңарчы ук билгеле иде бит сезгә. Мин

сезгә атымны иярләп куярга кушкан идем. Минем йомыш үтәлмәгәнмени әле?

— Үтәлгән, үтәлгән. Мөхтәрәм әфәнде, үз күзегез белән күреп ышана аласыз — атыгыз иярләнгән, капка төбендә тора.

— Яхшы, алайса мин әйткәнне эшләгез.

«Менә сиңа тамаша! Шул малай-шалайдан да курка микәнни?» — дип уйланды хуҗа.

Әмма ят кешенең боеручан күз карашын күргәч, ул уйларыннан бүленеп калды, ярашырга тырышкан бер кыяфәт белән баш иде дә чыгып китте.

«Миледины * күрмәсә генә ярар иде бу сукбай,— дип уйланды ят кеше.— Озакламый ул моннан узарга тиеш. Соңга да кала бугай инде. Каршысына чыксам, яхшырак булыр... Де Тревильгә дигән хатта ниләр язылганлыгын беләсе иде бит!..»

Шул рәвешчә, ят кеше, үз алдына пышылдап сөйләнә-сөйләнә, кухняга китте.

Ул арада трактир хуҗасы, ят кешенең кунакханәдән китүенә егет сәбәпче дигән нәтиҗә ясап, хатыны бүлмәсенә менде. Д'Артаньян инде тәмам һушына килгән иде. Син бай бер түрә белән гаугалаштың, шуның өчен сиңа полициянең бәйләнүе ихтимал, дигән мәгънәне аңлатып,— ят кешенең бай түрә икәнлегенә трактирчы шикләнми иде,— кунакханә хуҗасы д'Артаньянны, хәлсез булуына да карамастан, торып, үз юлына китәргә үгетли башлады. Д'Артаньян ярым аңгырайган хәлендә, камзулсыз, башын сөлге белән бәйләгән килеш, торып басты, үзен әкрен генә төрткәләп барган хуҗа ярдәмендә баскычтан төшә башлады. Кухня ишегеннән чыгып, тәрәзәдән тышка күз салуга, үзен мыскыл иткән теге адәмне күрде. Ул зур-зур ике Нормандия аты җиккән юл йөрү каретасының басмасына басып, кем беләндер тыныч кына сөйләшеп тора иде.

Аның белән сөйләшкән егерме-егерме ике яшьләрендәге яшь кенә бер хатынның карета тәрәзәсеннән башы күренеп тора иде. Без инде д'Артаньянның бер карауда ук кешенең бөтен йөз чалымнарын күреп алуын бер тапкыр әйтеп киткән идек. Ул әлеге ханымның яшь һәм чибәр булуын искәрде. Д'Артаньян үзе яшәгән көньяк Франциядә мондый йөзле хатыннар моңарчы бик сирәк очраганлыктан, хатынның сылулыгы егеткә аерата тәэсир итте. Ак йөзле, иң өсләренә хәтле сузылып төшкән аксыл-сары чәчле, моңсу зәңгәр күзле, алсу иренле, кершән төсле ак беләкле бер хатын иде ул.

— Димәк, кардинал хәзрәтләре миңа боера...— дигәне ишетелде ханымның.

— ...Хәзер үк Англиягә кайтып китәргә һәм, әгәр герцог Лондоннан чыгып китсә, шундук аннан хәбәр җибәрергә.

— Ә калган боерыклар?

---

* «Миледи» сүзенең фамилия алдыннан гына әйтелә торган сүз икәнен без, әлбәттә, беләбез. Әмма кулъязмада шул килеш очраткач, без инде аны үзгәртмәскә булдык.

— Калганнарын менә шушы тартмадан табарсыз — сез аны Ламаншның теге ягына чыккач кына ачарсыз.

— Бик яхшы. Ә сез үзегез ниләр эшләргә уйлыйсыз соң?

— Мин Парижга кайтам.

— Теге әшәке малайны акылга утыртмыйчамы?

Ят кеше нидер әйтмәкче булып авызын ачкан гына иде, бусагада аларның сөйләшкәнен ишетеп торган д'Артаньян күренде.

— Бу әшәке малай теләсә кемне үзе акылга утырта! — дип кычкырды ул.— Ышанам: хәзер ул акылга утыртырга җыенган кеше бу юлы аннан качып китмәстер дип беләм.

Ят кеше кашларын җыерып:

— Качып китмәс? — дип кайтарып сорады.

— Чибәр ханым күзе алдында качып китәргә йөрәгегез җитмәс дип уйлыйм.

Миледи, ят кешенең кылыч сабына үрелүен күреп:

— Исегездән чыгармагыз: азга гына тоткарлану да бөтен эшне харап итүе ихтимал! — дип кычкырды.

— Сез хаклы,— диде ят кеше тиз-тиз генә.— Сез үз юлыгыз белән китегез, мин — үз юлым белән.

Шулай дигәч, ул ханымга баш иде дә сикереп атына атланды, карета кучеры исә үз атларын чыбыркыларга керешге, ят кеше белән аның әнгәмәдәше, атларын җан-фәрманга чаптырып, икесе ике якка китеп бардылар.

— Ә счетны, счетны кем түли? — дип шырылдап кычкырды трактир хуҗасы. Мөхтәрәм кунагының акча түләмичә китеп баруын күргәч, кунакханә хуҗасының аңа карата булган ихтирамы көчле нәфрәткә әйләнгән иде.

Ят кеше, атын туктатмыйча гына, хезмәтчесенә:

— Түлә, хөрәсән! — дип кычкырды, шуннан соң хезмәтче трактир хуҗасының аяк астына берничә көмеш тәңкә ыргытты да түрәсе артыннан атын чаптырып китте.

Үз нәүбәтендә д'Артаньян да хезмәтче артыннан ташланып:

— Куркак җан! Кабахәт! Ялган дворян! — дип кычкырды.

Әмма егетнең бу хәтле үк йөрәк ярсуын күтәрерлек хәле юк иде әле. Ул йөгереп ун адым да китеп өлгермәде — колаклары шаулый, башы әйләнә башлады, күз алдын канлы болыт каплап алды, һәм шуннан соң ул гөрселдәп урам уртасына ауды да:

— Куркак җан! Куркак җан! Куркак җан! — дип кычкырып ята бирде.

— Чыннан да куркак җан икән шул! — дип, кунакханә хуҗасы д'Артаньян янына килде, юха теле белән бичара егетнең ышанычын яулап, бер мәсәлдә челән әкәм-төкәмне алдаган шикелле, егетне төп башына утыртырга чамалады.

— Әйе, котчыккыч куркак бәндә,— дип пышылдады д'Артаньян.— Аның каруы тегесе нинди чибәр!

— Тегесе кем? — дип сорады трактирчы.

Д'Артаньян пышылдап кына:

— Миледи,— диде дә тагын һуштан язды.

— Берни эшләп тә булмый. Икесен кулдан ычкындырдым инде. Аның каруы монысына ышаныч бар: бусы миндә берничә көн ятар әле. Ни дисән дә кулга унбер экю керәчәк,— дип сөйләнде трактир хуҗасы.

Кунагым көненә берәр экю акча түләп, унбер көн авырып ятар әле дип исәпләде трактирчы, тик бу кунагын белеп бетерми иде әле ул. Иртәгесе көнне д'Артаньян иртәнге сәгать биштә үк торды да үз аягы белән кухняга төште, берничә төрле үлән — аларның төгәл исемлеге безнең көнгә хәтле сакланмаган — шуның өстенә шәрап, май, розмарин китертте һәм, әнисе биргән рецептны кулына тоткан килеш, бәлзәм ясап, шуны тәнендәге яраларына сөртте, яраларын үзе бәйләде, янына берийнди табип китертмәде. Әлеге бәлзәмнең шифасы тигәндерме, әллә табиплар булмавы файда иттеме, тик ни булса да булды — д'Артаньян шул кичне үк торып аягына басты, икенче көнне инде сәламәтләнеп тә җитте.

Ләкин розмарин, май һәм шәрап өчен акча түләгәндә (егет, катгый диета саклап, бу көнне әнә шуларны гына тәгам итте, сары аты исә, кунакханә хуҗасының әйтүенә караганда, гәүдәсенә бәрабәр итеп исәпләгәндә өч тапкыр артыграк ашаган икән), д'Артаньянның кесәсендә таушалып беткән бәрхет янчыгы белән унбер экю акчасы гына бар, де Тревиль җәнапларына исеменә атап язылган хаты юкка чыккан иде.

Егет башта хатны ашыкмыйча, бик җентекләп эзләде. Бер егерме тапкыр чалбар һәм җилет кесәләрен актарып карады, юл букчасын кабат-кабат капшады. Хатның инде югалганлыгына берийнди шик калмагач, егетнең шулкадәр ачу-ярсуы кузгалды — шәрап белән теге хуш исле май яңадан кирәк була язды, чөнки кунак егетнең тузгынганын, хатны тапмасагыз, бу йорттагы бөтен нәрсәне кырып бетерәм дип дулый башлавын күргәч, кунакханә хуҗасы кулына күсәк алган, хатыны себерке тоткан, хезмәтчеләре исә моннан ике көн элек кенә кулланган таяклар белән коралланганнар иде.

— Хат кайда, хат?! — дип аваз салды д'Артаньян.— Табып бирегез хатымны, мәлгуньнәр! Югыйсә мин сезне божыр урынына тимер таякка тезәм!

Бәхетсезлегенә каршы, егетнең бу ниятен чынга ашырырга бер сәбәп комачаулык итте. Әйткәнебезчә, аның кылычы беренче сугышуында ук урталай сынган, егет моны бөтенләй исеннән чыгарган иде. Шуңа күрә ул кылычымны алам дип сузылуга, кынысыннан берничә дюйм озынлыгындагы кылыч сыныгы гына килеп чыкты, трактир хуҗасы аны бик әйбәтләп кире кынысына салды, оч ягы сыныгын исә, шпиклау энәсе ясарга кирәк булыр дип, җыеп куйды.

Трактир хуҗасы кунагының таләбен бик урынлы дип тап-

маса, безнең ярсу егетне, шәт, әлеге сәбәп кенә тыеп кала алмаган да булыр иде.

— Чыннан да, кая юкка чыкты икән соң ул хат? — диде хуҗа, күсәген кире төшереп.

— Әйе, әйе, кая киткән ул хат? — дип кычкырып җибәрде д'Артаньян.— Иң элек, мин сезне кисәтеп куям: ул хат де Тревиль җәнапларына атап язылган, шулай булгач, табылырга тиеш ул. Әгәр дә мәгәр табылмаса, де Тревиль әфәнде сездән таптырачак ул хатны, белеп торыгыз!

Бу сүз инде трактир хуҗасын тәмам куркуга төшерде. Король белән кардинал җәнапларыннан кала, де Тревиль әфәндене исеме гаскәриләр арасында гына түгел, кала кешеләре тарафыннан да бик еш телгә алына шикелле. Хәер, тагын «Жозеф ата» * да бар бит әле, әмма аның исемен шыпыртлап кына әйтәләр: кардинал Ришельеның дусты «Соры хәзрәттән» халык бик нык курка иде.

Кунакханә хуҗасы күсәген куеп, хатынына себеркесен, хезмәтчеләргә таякларын ташларга ымлап, татулашу билгесе күрсәтте дә хатны эзләргә кереште. Байтак эзләп тә берни таба алмагач:

— Ул хат эчендә берәр кыйммәтле нәрсәгез бар идеме әллә? — дип сорады.

— Бар иде шул! — диде Гасконь егете, шул хат ярдәмендә король сараена керергә исәп тота иде бит ул.— Минем бөтен байлыгым шул хат эчендә иде.

— Испан боны идеме әллә? — дип хафаланып сорады хуҗа.

— Король хәзрәтләренең үз казнасыннан акча ала торган бон,— диде д'Артаньян. Шул хат ярдәмендә корольгә хезмәткә керергә исәп тоткач, ул, ялганламыйча, болай зурдан кубыбрак җавап бирергә дә хакым бар дип уйлады.

— Ах, шайтан алгыры! — дип куйды трактир хуҗасы тәмам хафага төшеп.

— Анысына исем китми,— диде д'Артаньян Гасконь кешеләренчә эрәеп,— анысы ул хәтле түгел әле, акчасы да кечкенә нәрсә. Ә менә хат үзе бик кыйммәтле иде. Мин ул хатны югалтканчы мең пистоль акча югалтыр идем.

Кирәк санаса, ул «егерме мең» дип тә әйтә алган булыр иде дә, тик егетлек тыйнаклыгы белән генә тыелып калды.

Бөтен бүлмәләрне актарып хат эзләп йөргән хуҗаның башында кинәт нур чаткысы шикелле бер уй чагылып китте.

— Ул хат югалмаган бит! — диде трактирчы.

— Нәрсә? — дип кычкырды д'Артаньян.

---

* Жозеф ата — Жозеф де Трамбле (1577 елда туган) — «Жозеф ата» яки «Соры кардинал» дигән исеме белән билгеле. Кардинал Ришельеның иң интим эшләр буенча ышанычлы кешесе булган. Дан-шөһрәт сөюче, каты бәгырьле, каты куллы Жозеф ата, бернинди рәсми дәрәҗәсе булмаса да, зур йогынты һәм властька ия булган.

— Югалмаган. Сездән урлаганнар аны.

— Кем урлаган?

— Әнә кичәге теге ят дворян. Ул кухняга төшкәндә, сезнең камзулыгыз шунда ята иде. Анда ул берүзе генә нәрсәләрдер маташты. Валлаһи дип әйтәм, шуның эше генә ул!

— Шулай дисезме? — диде д'Артаньян ышанып җитмичәрәк.

Әлеге хатның бары тик үзе өчен генә әһәмияте барлыгын егет бик яхшы белә, шуңа күрә берәр кешенең бу хатка кызыгуын уена да китерми иде ул. Кунак йортында булган узгынчылар да, хезмәтчеләр дә ул хаттан берәр файда күрә алырлар дип шикләнерлек урын юк иде.

— Димәк, сез шул оятсыз дворяннан шикләнәсез? — дип кайтарып сорады д'Артаньян.

— Шул кеше икәнлегенә иманым камил,— диде хуҗа.— Мин аңа, сез мөхтәрәм әфәндегә де Тревиль җәнаплары ярдәм итә, сездә ул атаклы түрәгә хат та бар дигәч, ул борчуга төште, миннән: «Кайда ул хат?» — дип сорады, аннары шундук кухняга төшеп китте. Сезнең камзулыгызның анда икәнлеге мәгълүм иде аңа.

— Алайса шул урлаган! — диде д'Артаньян.— Мин моны де Тревиль җәнапларына әйтәчәкмен, ә ул корольгә җиткерәчәк!

Шуннан соң егет эре генә кыяфәт белән кесәсеннән ике экю акча чыгарып кунакханә хуҗасына тоттырды. Хуҗа исә, башыннан бүреген салып, аны капка төбенә хәтле озата чыкты. Егет кызгылт-сары аргамагына атланды да, бернинди маҗараларга юлыкмыйча, Париж каласының Сент-Антуан дигән капкасы төбенә чаклы барып җитте. Шунда д'Артаньян өч экю акчага аргамагын сатып җибәрде — монда килеп җиткәндә инде егет атны бик нык өшәндергән булуын да исәпкә алсак, өч экю акча ярыйсы гына бәһа иде. Шуңа күрә д'Артаньянның атын сатып алучы барышник егеткә әйтми калмады: атың бик сирәк очрый торган үзенә бер төсле булганы өчен генә шундый зур бәһа түләдем мин сиңа, диде.

Шулай итеп, д'Артаньян, төенчеген култык астына кыстырып, Парижга үз аягы белән җәяү килеп керде, кала урамнарында шактый йөргәннән соң, акчасына күрә бер бүлмә эзләп тапты. Люксембург янындагы Каберчеләр урамына урнашкан бу бүлмә чарлак бүлмәсе сыман бер нәрсә иде.

Д'Артаньян фатир хакын өлешчә алдан түләп куйды да чарлак бүлмәсенә менеп урнашты һәм бүгенге калган көнен эшләп уздырды: камзулы белән чалбарына ука текте — ул укаларны әнисе өлкән д'Артаньянның өр-яңа дип әйтерлек камзулыннан сүтеп алып, шыпырт кына улына биргән иде. Шуннан соң егет яр буендагы Тимер-томыр урамына барып, кылычына яңа оч куйдырды. Аннары Луврга барып чыкты, шунда очраган бер мушкетердан де Тревиль әфәнденең йортын сорады. Ул

йорт д'Артаньян урнашкан җиргә якын гына — Иске Күгәрчен оясы дигән урамда икән — егет бу хәлне дә яхшыга булсын дип юрады.

Шуннан соң инде ул үзенең Мёнг каласындагы тотышыннан бик канәгать булып, кылган гамәлләре өчен үкенмичә, бүгенге көненә ышанып, киләчәгенә зур өметләр баглап, ятты да баһадирларча каты йокыга талды.

Сәламәт провинциал буларак, иртәнге тугызларга хәтле йоклагач, егет торды да, өлкән д'Артаньянның әйтүенчә, король дәүләтендә өченче дәрәҗәдәге кеше булган атаклы де Тревиль җәнаплары янына китте.

## II

## *ДЕ ТРЕВИЛЬ ҖӘНАПЛАРЫНЫҢ КАБУЛХАНӘСЕНДӘ*

Де Труавиль әфәнде — аның Гасконьдагы нәсел-нәсәбе үзләрен әле һаман шул исем белән атап йөртә — яки де Тревиль — Парижга килгәч, исемен ул шулай дип йөртә башлаган иде — үзенең тормыш юлын чыннан да нәкъ д'Артаньян шикелле башлаган иде, ягъни аның да кесәсендә бер су * да акчасы юк иде, әмма де Тревильнең чаялыгы, үткен теле һәм тапкырлыгы җитеп ашкан, әнә шул сыйфатлары белән атасыннан каласы мираска гына өметләнеп яшәгән иң ярлы Гасконь дворяны да зур матди терәге булган иң бай Прегори яки Берри дворянына караганда зуррак уңышка ирешә иде. Аның кылычка кылыч килеп сугышканда искиткеч кыю-чая булуы, аннан да бигрәк дошманын гел җиңеп чыгуы де Тревильне король сараендагы уңыш дигән баскычның иң югары басмасына күтәрде, ул аңа берьюлы өчәр басма аша дигәндәй атлап-йөгереп менде.

Атасы Һенрих IV нченең истәлегән бик ихтирам иткән корольнең дусты иде ул. Де Тревиль әфәнденең этисе Лигага каршы сугышта корольгә зур тугрылык белән хезмәт итте, шуның өчен, акча җитмәү сәбәпле,— Беарн дворяны гомере буена акчага туймады, үзенең барлык бурычларын тапкыр сүзе белән генә кайтарып түләде, тапкырлыкны исә ул кешедән әҗәткә сорап тормый иде,— әйткәнебезчә, әнә шул акчасы җитмәү сәбәпле король аңа Парижны алганнан соң үз гербына кызыл җирлеккә арслан сурәте төшерергә һәм fidelis et fortis ** дигән девиз язып куярга рөхсәт итте. Мондый хөрмәтнең бәһасе бик зур булса да, зәмине бик аз иде шул. Шуңа күрә бөек Һенрихның данлы көрәштәше үлгән чагында улына мирас итеп кылычы белән девизын гына калдырды. Әнә шул мирас һәм керсез исеме аркасында де Тревиль әфәнде яшь принц сараена хезмәткә алынды, шунда ул үзенең әлеге девизына бик турылыклы

* Су — Франциядәге вак акча.
** Тугры һәм көчле (*латинча*).

рәвештә кылычы белән яхшы хезмәт итеп дан казанды, хәтта король дәүләтенең иң оста фехтовальщигы Людовик XIII, әгәр дусларымнан берәрсе дуэльдә сугышырга уйласа, секундант итеп иң элек үземне, аннары де Тревиль әфәндене чакырырга киңәш итәр идем, хәтта аны беренче урынга да куярга мөмкин, дип сөйләнә торган булды.

Людовик XIII де Тревильне чын-чыннан ярата башлады, дөрес анысы: аның яратуы корольләрчә эгоистик бер ярату иде, шулай да ярата иде. Моның хикмәте шул: ул авыр заманда түрәләр үз тирәләренә де Тревиль шикелле кешеләрне тупларга тырышалар иде. Де Тревильләр гербындагы «көчле» сүзен үзенең девизы итәргә теләүче кешеләр аз булмас иде, әмма шул язудагы «тугрылыклы» дигән сыйфатка дворяннарның күпмесе дәгъва итә алыр иде икән?!

Де Тревильнең исә моңа дәгъва итәргә хакы бар иде. Ул, хуҗасына турылыклы маэмай шикелле, аны-моны уйламыйча, боерыкка сукыр рәвештә буйсына белүче, зиһенле һәм нык куллы сирәк кешеләрдән иде. Күзләре аның корольнең берәр кешегә ачу тотканлыгын күреп алу өчен, ә кулы Бем яки Моревер, Польтро, де Мере яки Витриише гаеп эшләгән кешеләрне бетерү өчен хезмәт итә иде. Де Тревильгә үзен күрсәтер өчен моңарчы җай гына туры килми, мәгәр ул җай чыкканын көтә, каптырып алырга әзер тора иде. Шуңа күрә дә Людовик XIII де Тревильне үз мушкетерларының капитаны итеп куйды. Ординар сагы Һенрих III өчен, Шотландия гвардиясе Людовик XI өчен нинди хезмәт башкарган булса, Людовик XIII өчен бу мушкетерлар да шул ук рольне уйный иде.

Үз нәүбәтендә кардинал да бу яктан корольгә бирешми иде. Людовик XIII нең үз тирәсенә нинди дәһшәтле көч туплавын күреп, Франциянең бу икенче, дөресрәге — беренче хакиме дә үз гвардиясен булдырырга теләде. Шуңа күрә, Людовик XIII үз мушкетерларын булдырган кебек, ул да үзенә мушкетерлар җыйды. Шул рәвешчә, бер-берсеннән көнләшеп яшәүче бу ике хаким Франциянең барлык төбәкләреннән һәм хәтта чит дәүләтләрдән дә гаскәри батырлыгы белән дан казанган гайәр кешеләрне җыялар иде. Ришелье белән Людовик XIII кичләрен шахмат уйнаганда еш кына үз егетләренең булдыклылыгы турында бәхәсләшеп китәләр. Һәркайсы үз мушкетерларының гаскәриләрчә ыспайлыгы һәм кыюлыгы-чаялыгы белән мактана, үзара сугышу һәм дуэльләрне сүздә яманласалар да, үзләренең ян сакчыларын астыртын гына сугышырга котырталар иде. Үз мушкетерларының җиңүе аларга чиксез шатлык китерә, җиңелүләре исә чын-чыннан кайгы-хәсрәткә төшерә иде. Мәсәлән, әнә шундый бик күп җиңүләргә катнашкан һәм берничә тапкыр җиңелүгә дә дучар булган бер кеше үзенең мемуарларында шулай дип бәян кыла.

Тревиль үз хакименең йомшак кылын сизеп ала, шуның нәтиҗәсендә дуслыкны тиз ташлаучан корольне озак вакытлар

буена үзенә каратып тора. Аның үз мушкетерларын парад маршы белән кардинал Арман дю Плесси Ришелье каршыннан уздыргандагы ачу китергеч кыяфәте кардинал хәзрәтләренең чал мыегын ярсудан шырпы шикелле тырпаерга мәҗбүр итә. Тревиль, сугыш вакытында я дошманы, я ватандашлары исәбенә яшәгәндә, ул заманның сугыш осталыгын бөтен нечкәлекләренә хәтле белеп эш итә, аның солдатлары Тревильнең бер үзенә генә буйсынган башкисәрләр легионына әйләнәләр.

Шапшак киенгән, битләре тырналып беткән кызмача король мушкетерлары, дөресрәге — де Тревиль әфәнде мушкетерлары, мәйханәләрдә, күңел ача, кәеф чигә торган урыннарда тулганалар, мыекларын бөтергәләп, кылычларын селтәп акыраларбакыралар, юлларында кардиналның сакчылары очраса, аларга аерата үчегеп бәйләнә башлыйлар. Аннары инде, әлләниләр такмаклый-такмаклый, кыныларыннан кылычларын суырып чыгаралар. Кайчакны аларның үзләрен үтереп тә китәләр, һәм алар үлгәндә дә, безнең өчен кайгырып еларлар, безнең өчен үч алырлар, дигән ышаныч белән үлә, күбрәк исә алар үзләре үтерә, аларны төрмәдә черетмәячәкләренә, де Тревиль җәнаплары һичшиксез коткарачагына ышанып эш итәләр. Бу кешеләр де Тревиль әфәндене ничек кенә мактамыйлар, аны алла урынына күрәләр һәм үзләре бик башсыз-чая булсалар да, аның алдында, укытучысы каршындагы бала шикелле, дер калтырап торалар, кушканын һичбер карышусыз үтәргә керешәләр, аның кечкенә генә шелтәсен дә өсләреннән юып төшерү өчен үләргә дә әзер торалар иде.

Де Тревиль әфәнде баштарак бу көчле рычагны король һәм аның тарафдарлары файдасына кулланды, аннары үзе һәм дуслары файдасына эш итә башлады. Хәер, ул заманның бер генә мемуарында да, хәтта дошманнарыныкында да,— ә де Тревильнең каләм белән эш итүчеләр арасында да, кылычлылар арасында да андый дошманнары байтак булган,— әйе, дошманнарының мемуарларында да бу намуслы кешенең турылыклы солдатларына күрсәткән ярдәме өчен нинди дә булса әҗер алганлыгы әйтелми. Интрига кору мәсьәләсендә иң оста интриганнардан да остарак булса да, ул намуслы, гадел кеше булып кала бирә. Алай гына да түгел: коточкыч авыр походларда йөрүенә, гаскәри тормышның газап-михнәтләренә карамастан, ул күңелле-кызык мажаралар өчен җан атучы, җае чыкканда нәзакәтле мадригал биеп, хатын-кыз күңелен бик оста аулый белүче бер кеше дә була. Егерме еллар элегрәк Бассомпьерның * гыйшык мажаралары турында күпме сүз йөргән булса, де Тревильнең хатын-кыз күңелен аулавы турында да шун-

---

* Бассомпьер Франсуа (1579—1646) — Франция маршалы һәм дипломат. Ришельегә каршы сарай интригасына катнашкан һәм уңышсызлыкка очрагапнан соң кодрәтле кардинал әмере белән унике ел төрмәдә утырган.

дый ук гайбәт тарала,— моның инде үзенә күрә мәгънәсе бар. Мушкетерлар капитанына соклананалар, аннан куркалар, аны яраталар-сөяләр, икенче төрле итеп әйткәндә, ул иң зур бәхет һәм уңышка ирешә.

Людовик XIV үз сараендагы барлык вак йолдызларны күз камаштыргыч балкышы белән каплап, аларның нурын сүрелдерде, аның атасы исә, pluribus impar * кояш, үзенең яраткан, якын кешеләренә үз нурлары белән балкырга мөмкинлек бирә. Король белән кардиналдагы иртәнге кабул итүдән башка, Парижда тагын аерым игътибарга лаеклы ике йөздән артык «иртәнге кабул итү» була. Болар арасында де Тревильнең иртәнге кабул итүенә иң күп кеше җыела иде.

Аның Иске Күгәрчен оясы урамындагы йортының ишегалды җәй көне иртәнге сәгать алтыдан, кыш көне сигездән үк инде гаскәри лагерьга охшап кала. Ишегалдында һәрвакыт баштан-аяк коралланган, ни кушсаң, шуны үтәргә әзер булган илле-алтмышлап мушкетер йөреп тора — саннары күп булып күренсен өчен, алар билгеле бер вакыт саен алмашынып торалар иде, күрәсең. Гаҗәеп киң баскычтан — хәзерге төзүче аның урынына зур бер йорт салып куя алыр иде — әле аска, әле өскә берәр төрле ярдәм эзләп килүчеләр, провинциядән килгән, мушкетерлыкка язылырга ашкынып торган дворяннар, үз хуҗаларыннан хат китергән, алтын укалы кием кигән лакейлар йөреп тора. Кабул итү бүлмәсендә стена буендагы эскәмияләрдә сайланган, ягъни хуҗа тарафыннан чакырылган кешеләр утыра. Бу бүлмәдә иртәдән алып кичкә кадәр кеше тавышлары гөрләп тора, шул ук вакытта исә де Тревиль янәшәдәге кабинетында кунаклар кабул итә, аларның шикаятьләрен тыңлый, тиешле боерыкларын бирә һәм, Луврда король үз балконына чыгып кергән шикелле, тәрәзә янына барып үзенең кешеләренә һәм коралларына да күз салып килә.

Д'Артаньян беренче тапкыр бирегә килгән көнне монда җыелган халык бигрәк тә провинциал күзенә гаҗәп күп булып күренде. Провинциал дигәнебез, әлбәттә, Гасконь егете иде, ә аның якташлары ул заманда бернигә дә исләре китми торган булулары белән дан тота иде. Дүрткел эшләпәле озын кадак сугып чыгылган бик дәү капканы үтеп кергәч тә йомышлы кеше коралллы гаскәриләр төркеме эченә килеп эләгә. Ишегалдында тулганып йөрүче бу кораллылар бер-берсенә кычкырып эндәшәләр, әле уен уйнарга керешәләр, әле бәхәсләшеп-талашып та китәләр. Шушы кайнап торган кеше дулкыннары аша юл ярып узу өчен офицер, бай бер түрә яисә сөйкемле, чибәр бер ханым булу кирәк.

Безнең егетебез, йөрәге ашкынып типкән хәлдә, чамасыз озын кылычын ябык ботларына кысып, киң кырыйлы эшләпәсен кулы белән тоткан килеш, уңайсызлануын яшерергә тырыш-

---

* Күпләр тиң булмаган (*латинча*).

кан провинциал шикелле мескен бер кыяфәттә елмая-елмая, шушы этешкән-төртешкән, кысылышкан төркемнәр аша юл ерып китте. Теге яки бу төркемне узганнан соң, ул беркадәр җиңел сулап куйды, шулай да артыннан кешеләр карап калганлыгын сизеп торды, һәм моңарчы үзе турында гел яхшыны гына уйлаган д'Артаньян гомерендә беренче тапкыр үзен бик уңайсыз, көлке бер хәлдә кебек хис кылды.

Баскыч төбенә җиткәч инде хәле тагы да кыенлаша төште. Баскычның аскы басмаларында дүрт мушкетер кылыч уены уйнап маташалар, аларның баскыч төбенә җыелган уилап-егермеләп дусты исә уенга катнашыр өчен чират көтеп торалар. Теге дүртнең берсе бер басма өскәрәк менеп баскан да, кулына ялангач кылыч тотып, калган өчесен баскычтан менгезмәскә тырыша. Теге өчесе дә кылычларын уйнатып моңа һөҗүм итәләр иде.

Д'Артаньян башта бу кылычларны очлары капланган фехтование рапирасы түгелме дип уйлаган иде. Тик озакламый, уенга катнашучыларның битләре тырнаштырылганын күргәч, кылычлары бик очлы һәм үткен икәнлегенә төшенде. Берәрсенең бите тырналган саен, уенны карап торучылар гына түгел, яраланучылар үзләре дә шаулашып көләргә тотыналар иде.

Бу минутта өске басмада торучы мушкетер үзенең дошманнарына каршы бик оста, бик җитез сугыша иде. Алар тирәсенә халык җыелды. Уенның шарты шуннан гыйбарәт икән: уенга катнашучы кеше беренче тапкыр яралану белән үк уеннан чыга да аның аудиенциягә булган чираты җиңүче кешегә күчә икән. Нибары дүрт-биш минут эчендә тегеләрнең өчесенә дә кылыч очы тиде; берсенең кулы тырналды, икенчесенең ияге, өченчесенең колагы сыдырылды, басманы саклаучы мушкетерга исә бер тапкыр да тидерә алмадылар. Уен шарты буенча, мондый чаялык өчен җиңүче кеше чиратта өч урынга алгарак уза иде.

Моның белән генә безнең сәяхәтче егетебезнең исен китәрү, дөресрәге — исе киткәнлеген сиздертү бик кыен булса да, бу уенга ул барыбер шаккатты. Аның туган җирендә, кызу канлы кешеләр яшәгән якта, дошманыңны дуэльгә чакыру өчен нинди дә булса бер сәбәп кирәк. Дүрт уенчының болай шаяруы Гасконь ягының үзендә ишетеп белгәннәреннән дә гаҗәбрәк булып күренде. Ул үзен Гулливерның котын алган атаклы великаннар иленә килеп эләккән сыман хис кылды. Әмма максатка барып җитәргә әле шактый ерак: баскычның өске идәненә менәсе, аннары кабул итү бүлмәсенә эләгәсе бар иде.

Өске идәндә инде кылыч белән сугышмыйлар — анда хатын-кыз җенесе хакында ләчтит саталар, ә кабул итү бүлмәсендә король сараеның гайбәтләрен сөйләшәләр иде. Д'Артаньян өске идәнгә менгәч кызарынды-уңайсызланды, кабул итү бүлмәсенә кергәч исә йөрәге үк калтырана башлады. Гасконьда чагында аны яшь кенә асрау кызлар, вакыт-вакыт хәтта яшь хуҗабикәләр өчен дә хәтәр генә егет иткән тапкыр, кыю хыялы

беркайчан да, хэтта кызышып саташкан чагында да монда сөйләнгән гыйшык мажараларының яртысын да, гашыйк каһарманлыкларының хэтта чирегеп дә күз алдына китертә алмас иде, өстәвенә әле, боларны атаклы кешеләр исеме белән бәйләп, иң яшертен нечкәлекләренә хэтле тәфсилләп сөйлиләр иде. Шулай итеп, баскыч өстендә чакта д'Артаньянның әдәп-инсафына көч китерсәләр, кабул итү бүлмәсендә исә аның кардиналга карата булган ихтирамын какшаттылар. Д'Артаньян биредә бөтен Европаны дер селкетеп торган политиканы ничек тәнкыйть итүләрен үз колагы белән ишетеп шаккатты. Аның белүенчә, кардиналның шәхси тормышы серләрен төпченергә маташкан өчен генә дә берничә бай түрә зарар күргән булса да, монда кардинал хэзрәтләренең шәхси тормышына тел тидерәләр иде. Де Тревиль эфәндөнең мушкетерлары д'Артаньянның этисе тарафыннан бик ихтирам ителгән бу бөек кешене бер адәм көлкесенә әйләндергәннәр иде. Алар аның камыт аякларыннан, бөкрәя башлаган аркасыннан көләләр; берничәләре аның сөяркәсе мадам д'Эгильон, туганнан туган сеңлесе де Комбалэ ханым турында җыр җырлап та ала, калганнары исә шунда кардиналның пажлары һәм сакчыларыннан көлеп шаяртырга сүз куешалар иде — болар барысы д'Артаньянга акылга сыймаслык гайре табигый бер нәрсә булып тоелды.

Кардиналга кагылышлы бу усал эпиграммаларга инде король исеме дә килеп керсә, күзгә күренми торган ниндидер бер кул шул минутта ук тегеләрнең ерык авызларын каплый сыман иде. Сөйләшеп торучылар, тавышыбыз стена аша де Тревиль эфәнде кабинетына ишетелмәгәе дип шикләнгән кебек, як-якка карана башлыйлар. Тик берәрсе шунда кинаяле итеп сүз кыстырып җибәрүгә, гәп яңадан кардинал хэзрәтләренә күчә, кешеләр тагын кычкырып сөйләшергә керешәләр, шулай итеп, бөек кардиналның бер генә эше гамәле дә күләгәдә торып калмый иде.

«Бу кешеләрнең барысын, тәгаен, Бастилиягә ябып, асып үтерәчәкләр. Болар белән бергә мине дә эләктерәчәкләр: аларның ни сөйләшүләрен ишетеп-тыңлап торгач, мине дә алар ишенгән дип санаячаклар. Әти мине кардиналга карата бик ихтирамлы итеп тәрбияләргә тырышкан иде бит. Әгәр ул минем шушы хөр күңелләләр арасында булуымны белсә, ни әйтер иде икән?!» — дип коты чыгып уйланды д'Артаньян.

Шуңа күрә ул, аңлашылганча, сүзгә катнашып китәргә батырчылык итмәде. Әмма егет барысын да бик нык күзәтеп, һәммә тойгысын да эшкә җигеп, йотлыгып тыңлап торды, берсен дә игътибарыннан ычкындырмаска тырышты. Атасының үгет-киңәшләрен бик олыласа да, ул үз күңеле кушканнардан һәм зәвыкларыннан чыгып, үз тирәсендәге хәлләрне гаеп итүдән бигрәк хуплау ягында тора иде.

Шулай да де Тревильне яратучы шушы халык төркеме арасында аның бөтенләй чит кеше булуын һәм биредә беренче

тапкыр күренүен искәреп, егеттән ни йомыш белән йөрүен сорадылар. Д'Артаньян тыйнак кына итеп үзенең исемен әйтте һәм, де Тревильнең якташы икәнлеген искәртеп, егетнең йомышын сорарга килгән хезмәтчегә де Тревиль әфәндедән берничә генә минутка үзен кабул итүен үтенергә кушты. Хезмәтче ярдәм күрсәтергә теләгән бер тон белән, вакыты җиткәч, аның үтенечен тапшырырга вәгъдә итте.

Баштагы уңайсызлануларыннан беркадәр арына төшкәч, д'Артаньян тирә-ягындагы кешеләрнең өс-башына, йөз-кыяфәтләренә дә күз төшерерлек хәлгә килде.

Иң шау-шулы бер төркемнең үзәгендә озын буйлы, масайган кыяфәтле, бөтен кешенең игътибарын җәлеп итәрлек гаҗәеп киемле бер мушкетер басып тора иде. Аның өстендә гаскәри мундир түгел (хәер, ирек азрак, бәйсезлек күбрәк булган ул заманнарда андый мундир кию мәҗбүри саналмаган), бәлки аксыл-зәңгәр төсе шактый уңган, таушалган камзул, камзул өстеннән алтын ука белән чиккән зиннәтле җилкә каешы кигән, шул зиннәтле каеш аяз көнне су өстендәге кояш таңкәләре шикелле җем-җем итеп җемелдәп тора иде. Ал бәрхеттән теккән озын итәкле плащы бик нәфис булып иң өстеннән аска таба сузылып төшкән, тик плащының изү турысы гына ачык, шуннан бик озын кылыч асылган әлеге җемелдек каеш күренеп тора иде.

Бу мушкетер әле яңа гына каравылдан алмашынган икән, салкын тидергәнмен дип зарланып, юри йөткеренгәләп ала. Мыегын бөтергәләп, исе китмәгән кыяфәт белән генә, менә шуңа күрә өскә плащны кияргә туры килде әле, дигән була, тирәсендәге кешеләр исә, бигрәк тә д'Артаньян, ах итеп аның алтын укалы каешына сокланып торалар.

— Берни дә эшләр хәл юк, хәзер инде бу модага кереп бара. Моның бушка мал әрәм итү икәнен үзем дә беләм, шулай да модалы. Хәер, атай акчасын нәрсәгә булса да тотарга кирәк бит,— ди мушкетер.

— Һәй, Портос,— диде шунда арадан берәү,— син безне атайның юмартлыгы аркасында шушы алтын бауга тиештем дип ышандырырга тырышма әле! Якшәмбе көнне Сент-Оноре капкасы янында битенә вуаль бөркәнгән бер хатын белән очраткан идем бит мин сине — шул хатын бүләк итмәде микән моны?

— Юк, дворян буларак ант итеп әйтәм: мин аны үз акчама сатып алдым,— дип җавап кайтарды Портос дигәннәре.

— Әйе, әйе, нәкъ менә мин шушы яңа янчыкны сатып алган шикелле: мин дә иске янчыгыма сөяркәм салган акчага менә яңасын юнәттем,— дип сүз кыстырды тагын бер мушкетер.

— Юк, валлаһи, алай түгел,— диде Портос,— шушыңа унике пистоль акча түләгәнлегемә мин дә дәлил китерә алам.

Сокланып шаулашкан тавышлар көчәйсә дә, шик һаман бетмәгән иде әле.

— Шулай бит, Арамис? — диде Портос икенче бер мушкетерга.

Бу мушкетер үзенә Арамис дип эндәшкән егетнең нәкъ капма-каршысы иде. Ул егерме ике-егерме өч яшьләрендәге, беркадәр төчерәк елмаеп торган эчкерсез чырайлы, кара күзле, көз көне өлгереп җиткән шәфталу җимешендәге шикелле, алсу яңакларын йомшак кына мамык төк баскан бер егет иде. Иреге өстендә як-якка матур гына, тигез генә булып мыегы сызылып тора. Үзе, әйтерсең беләк тамырларым бүртеп кабармагае дип, кулларын аска төшерергә курка. Колак яфракларының үтә күренердәй нәфис алсулыгын сакларга тырышкан сыман аратирә колакларын тоткалап ала. Үзе аз сөйләшә, сүзен ашыкмыйча, җайлап кына әйтә, ара-тирә башын да игәли, бик матур тешләрен күрсәтеп тавышсыз гына көлеп тә куя — үзенең килеш-килбәтенә бик игътибар иткән кебек, тешләренә дә әһәмият итә иде, күрәсең. Дустының соравына каршы ул аның сүзен раслап баш кына какты.

Аның шул баш кагуы алтын бауга карата булган шикне бетерде дә булса кирәк. Ул бауга әле һаман сокланасалар да, бу хакта инде сөйләшмәс булдылар, шулай итеп, көтелмәгән ассоциацияләргә әкренләп буйсына-буйсына, сүз икенче темага күчте.

Шунда икенче бер мушкетер, үз тирәсендәгеләрнең бөтенесенә берьюлы мөрәҗәгать иткән кебек:

— Де Шале җәнапларының өлкән атбагары сөйләгәннәргә карата сезнең фикерегез ничек? — дип сорады.

— Ә ул ни сөйли соң? — дип эре генә итеп кайтарып сорады Портос.

— Ул Брюссельдә кардиналның иң турылыклы хезмәтчесе Рошфор белән очраштым, ди. Рошфорның өстендә капуцин киеме булган, шул маскарадыннан файдаланып, әлеге нәләт Рошфор де Лэга әфәндене төп башына утырткан.

— Төп башына утырткан, имеш. Дөрес микән соң ул хәл? — диде Портос.

— Мин аны Арамистан ишеттем,— диде мушкетер.

— Чынлапмы?

— Сез ул хәлне бик яхшы беләсез ич инде, Портос,— диде Арамис.— Кичә үк сөйләгән идем ич сезгә. Ул сүзгә яңадан әйләнеп кайтырга кирәк түгел.

— «Әйләнеп кайтырга кирәк түгел», имеш! — диде Портос.— Сез шулай дип уйлыйсызмы? «Әйләнеп кайтырга кирәк түгел!» Аһ, шайтан алгыры, бигрәк тиз хәл итәсез инде!.. Бигрәк тиз! Кардинал дворян кеше артыннан шымчылык итә, дарга асылырга тиешле юлбасар, хыянәтче бер кеше кулы белән ул аның хатларын урлый һәм, шул ук шымчыдан файдаланып, әлеге хатлар нигезендә Шалене җәзалап үтерергә тырыша: янәсе, Шале, корольне үтертеп, герцог Орлеанлыны королевага өйләндерергә ниятләнгән! Бу табышмакның серенә берәү дә

төшенә алмаган. Сез, гаҗәпкә каршы, аны безгә кичә генә хәбәр итәсез һәм, без әле шуны төшенеп тә җитмәстән, бүген инде: «Бу хәлгә әйләнеп кайтырга кирәк түгел»,— дисез!

— Ярый алайса, бик теләсәгез, ул хәлгә әйләнеп кайтабыз,— диде Арамис сабыр гына.

— Мин де Шале җәнапларының атбагары булсам, бик шәп итеп ул Рошфорның арт сабагын укытыр идем! — диде Портос кайнарланып.

— Ә сезнең арт сабагыгызны Кызыл Герцог укытыр иде,— диде Арамис тыныч кына.

— Кызыл Герцог! Браво, браво! Кызыл герцог! — дип Портос кулларын чәбәкләп, «әйе, әйе» дигәндәй баш каккалап кычкырып җибәрде.— Кызыл Герцог — бик шәп әйтелде бит бу. Бер дә борчылмагыз: бу тапкыр сүзне таратырга тырышырмын мин. Һай, үткен дә телле инде бу Арамис!.. Тик бу сәләтегезгә ярашлы мөмкинлек булмавы гына кызганыч, дустым. Нинди оста аббат чыккан булыр иде үзегездән!

— Һи, мин әле ул хыялымны вакытлыча гына ташлап торам,— диде Арамис.— Кайчан да бер аббат булачакмын әле. Минем, шуны күздә тотып, дин китаплары укыганымны беләсез бит, Портос.

— Үз дигәненә ирешер ул. Иртәме-соңмы — барыбер ирешми калмас,— диде Портос.

— Аның шкафында мушкетер киеме артында рухани җиләне эленеп тора — әнә шуны яңадан киеп алу өчен ул бер генә нәрсә көтә,— дип куйды бер мушкетер.

— Ә нәрсә көтә соң ул? — дип сорады икенчесе.

— Королеваның илгә варис бүләк иткәнен.

— Әфәнделәр, бу нәрсә белән шаярырга кирәкми,— диде Портос.— Королева әле, аллага шөкер, карт түгел, илгә варис бүләк итәрлеге бар.

— Лорд Бекингэмны * Франциягә килгән диләр! — дип хәйләкәр генә көлеп куйды Арамис, аның бу көлүе бернинди кинаясез кебек күренгән әлеге сүзенә икенче бер мәгънә төсмере өстәгән сыман булды.

— Арамис, дустым, менә бу юлы инде сез хаклы түгел,— диде Портос, аның сүзен бүлеп,— тапкыр әйтергә яратуыгыз сезне кайвакыт мәгълүм чикләрне узып китәргә мәҗбүр итә. Әгәр дә Тревиль җәнаплары ишетсә, мондый сүзегез өчен башыгыздан сыйпамас үзегезне.

— Сез миңа акыл өйрәтергә җыенмыйсыздыр бит, Портос? — диде Арамис, юаш күзләрендә кинәт яшен чаткылары ялтырап китте.

— Дустым, я мушкетер, я аббат булыгыз, әмма берьюлы икесе-дә булырга тырышмагыз,— диде аңа Портос.— Хәтерлә-

---

* Бекингэм Джордж Виллье, лорд (1592—1628) — Англиянең политик эшлеклесе, корольләр Яков I белән Карл I нең фавориты.

гез әле, шушы арада гына Атос сезгә әйткән иде бит: сез бөтен табыннан азыкланасыз, дигән иде... Юк, юк, үтенеп сорыйм, талашмыйк. Кирәге юк. Безнең өчебез — сез, мин һәм Атос арасында килешенгән шарт бик яхшы мәгълүм. Сез бит д'Эгильон ханым янына барып йөрисез, аның күңелен күрергә тырышасыз; сез де Буа-Траси ханым янына да, ягъни де Шеврез ханымның туганнан туган сеңлесе янына да йөрисез һәм, әйтүләренә караганда, ул ханым сезне бик ярата, имеш. Ай аллам, сезнең «бәхетле мин» дип икърар итәсегез юк, бераү дә сездән җаныгызны ачып салуны сорамый — сезнең тыйнак кеше икәнлегегезне кем белми! Әмма инде сезнең, шайтан алгыры, шундый эндәшмәү сәләтегез бар икән, ул чагында королева турында сүз чыкканда да ул сәләтегезне онытмагыз инде. Король белән кардинал турында теләсә кем теләсә ни сөйләсен, әмма королева — изге, аның турында сөйләсәләр тик яхшысын гына сөйләсеннәр.

— Портос, сез, Нарцисс кебек, үз-үзегезгә артык ышанасыз, исегездә тотыгыз моны, — диде Арамис. — Минем үгет-нәсихәт тыңларга яратмавым, фәкать Атос киңәшенә генә колак салуым сезгә мәгълүм бит. Ә менә сезгә килгәндә, кадерлем, ул артык зиннәтле каешыгыз сезнең саф тойгылы булуыгызга әллә ни ышаныч тудырмый. Мин үзем кирәк дип тапсам, аббат та булырмын. Ә хәзергә мин мушкетер һәм мушкетер буларак телемә ни килсә, шуны әйтәм. Хәзер менә минем сездән тәмам гарык булганлыгымны әйтәсем килде.

— Арамис!

— Портос!

— Әфәнделәр! Әфәнделәр! — дигән тавышлар ишетелде төрле тарафтан.

Лакей кабинет ишеген ачып җибәрде дә, әлеге тавышларны бүлеп:

— Де Тревиль җәнаплары д'Артаньян әфәндене көтә! — дип кычкырды

Лакей шушы сүзне әйтеп бетергәнче кабинет ишеге ачык торды һәм бу хәлне күреп бөтен кеше тын калды. Шул тынлыкта Гасконь егете алгы бүлмә аша узды да, әлеге сәер бәхәснең җәнҗалына катнашудан бик вакытлы котылуына чын күңеленнән сөенеп, мушкетерлар капитаны янына кереп китте.

## *III*

## *АУДИЕНЦИЯ*

Де Тревиль әфәнде бик кәефсез булса да, үзе алдында җиргә чаклы диярлек сыгылып баш игән егетне әйбәт кенә каршы алды һәм аның сәламен көлемсерәп тыңлап торды. Егетнең Беарн акценты де Тревиль әфәнденең яшь чакларын, туган якларын — теләсә нинди яшьтә дә кешенең күңелен кузгата

торган хатирәләрне исенә төшерде. Тик шунда ук ул, кабул итү бүлмәсенең ишегенә якынрак килеп, иң элек башкалар белән сүзне бетерергә, аннары инде д'Артаньян белән сөйләшә башларга дип егеттән рөхсәт сораган шикелле кулын күтәргәч:

— Атос! Портос! Арамис! — дип өч исем кычкырды, һәр исемне кычкырган саен тавышы көчәя барып, анда боерудан алып ярсуга хәтле булган барлык төсмерләр яңгырады.

Исемнәре икенче һәм өченче итеп әйтелгән безгә таныш ике мушкетер шундук иптәшләреннән аерылып, кабинетка керделәр, бусаганы атлап узу белән артларыннан шартлатып ишекне яптылар. Бу минутта бик үк тыныч-сабыр булмасалар да, үз-үзләрен бер үк вакытта горур да, буйсынучан да кыяфәттә бик иркен тотулары д'Артаньянны таң калдырды, ул аларны ярым илаһи бер кешеләр итеп, башлыкларын исә яшен яшьнәтеп, күкләр күкрәтүче Юпитер итеп күз алдына китерде.

Ике мушкетер кереп, кабинет ишеге ябылгач, алгы бүлмәдә сөйләшкән тавышлар яңадан көчәйгәч, (мушкетерларны кабинетка чакырып алу андагы халык өчен яңа азык булды, күрәсең), һәм, ниһаять, де Тревиль әфәнде смотрдагы шикелле туп-туры һәм тып-тын басып торган Портос белән Арамис янышнан кашларын җыерып кына өчме-дүртме тапкыр узгач, капыл гына алар каршысына туктады да тегеләрне ачулы бер кыяфәт белән баштан-аяк сөзеп:

— Кичә генә королънең миңа нәрсә әйткәне мәгълүмме сезгә, әфәнделәр? Мәгълүмме? — диде.

Чак кына сүзсез торганнан соң, ике мушкетер икесе берьюлы:

— Юк. Юк, әфәндем, безгә берни дә мәгълүм түгел,— дип җавап кайтардылар.

— Шулай да сез ул хакта безгә әйтерсез дип ышанабыз,— диде Арамис искиткеч бер әдәп белән һәм бик нәзакәтле итеп баш иеп алды.

— Король әйтте: моннан ары мушкетерларны кардинал хәзрәтләре гвардиячеләре арасыннан сайлап алам, диде.

— Кардинал хәзрәтләре гвардиячеләре арасыннан? Ничек инде ул алай? — дип кычкырып җибәрде Портос.

— Ул үзенең әчеп беткән шәрабына яхшы шәрап өстәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килгән.

Ике мушкетер да колак яфракларына хәтле кызарышып киттеләр. Д'Артаньян да үз-үзен кая куярга белмәде, җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрдәй булды.

— Әйе, әйе,— диде мушкетерлар капитаны тагы да кыза төшеп.— Король хәзрәтләренең сүзе хак, чөнки, ант итеп әйтәм, мушкетер әфәнделәрнең король сараендагы рольләре бернигә дә ярарлык түгел! Кардинал хәзрәтләре кичә кич шахмат уйнаганда кызганган бер тавыш белән сөйләргә кереште (аның шундый тавыш белән сөйләве минем ачуыма тиде): ул мәлгунь мушкетерлар, ул башкисәрләр, ди (бу сүзләрен аеруча

мыскыл итеп әйтте, монысы тагы да ачуыма тиде) — ул җәнҗалчылар, ди, үзе кыргый мәченеке төсле күзләре белән миңа карый,— рөхсәт ителгән вакыт узганнан соң Феру́ урамындагы мәйханәдә булганнар, ди. Аның тәртип тикшереп йөрүче гвардиячеләре,— шул вакыт йөземә карап шаркылдап көлеп җибәрә дип торам,— төнге тынычлыкны бозучы бу кешеләрне тотып алып китәргә мәҗбүр булганнар. Нәләт яугыры! Моның ни икәнен беләсезме сез? Мушкетерларны кулга алганнар бит! Сез дә шул компаниядә булгансыз... Әйе, әйе, яшереп маташмагыз, сезне таныганнар, кардинал сезнең исемегезне дә әйтте. Мин гаепле, мин үзем гаепле, чөнки кешеләремне мин үзем сайлап алам. Менә, әйтик, сез, Арамис: үзегезгә рухани җиләне бик килешә торып, нигә сез миннән мушкетер камзулы сорап алдыгыз? Ә менә сез, Портос... Сезгә шундый зиннәтле алтын бау салам кылыч тагып йөрер өчен кирәктер, шулаймы? Ә Атос... Атосны күрмим мин. Кайда ул?

— Әфәндем, авырый ул, бик каты авырый,— диде Арамис күңелсез генә.

— Авырый? Бик каты авырый, дисезме? Ни булган аңа?

— Чәчәк авыруы булмагае дип шикләнәләр, әфәндем,— диде Портос сүзгә кысылырга тырышып.— Бик күңелсез хәл инде: ул авыру аның бөтен битен харап итүе бар.

— Чәчәк авыруы дисезме?.. Бик мәзәк нәрсә сөйлисез бит әле сез, Портос! Аның яшендә чәчәк авыруы белән авыру! Юк, юк!.. Я ул яралангандыр... я үтергәннәр аны... Их, белә алсам!.. Нәләт яугыры! Мушкетер әфәнделәр, мин үз кешеләремнең ярамаган шикле җирләрдә йөрүен, урамнарда җәнҗал чыгарып, караңгы тыкрыкларда кылыч белән сугышуларын теләмим! Ахыр чиктә, үз кешеләремнең кардинал хәзрәтләренең гвардиячеләре каршында адәм көлкесенә калуларын теләмим мин. Әлеге гвардиячеләр тыныч-сабыр егетләр, тәртипле, чая егетләр. Аларны кулга аласы юк, аннары алар үзләрен кулга алдырмыйлар да. Монысына минем иманым камил! Баскан урыннарында үлсәләр үләрләр, әмма бер адым да артка чикмәсләр алар. Йөгерә-чаба качып котылуны фәкать король мушкетерлары гына булдыра ала!

Портос белән Арамис ачу-ярсуларыннан калтырана ук башладылар. Әгәр де Тревиль әфәндене́ң үзләрен чын күңелдән ярата́нга гына шулай сөйләгәнен белмәсәләр, алар аны буып, өзгәләп ташларлар иде. Егетләр, түзмичә, үкчәләрен келәмгә бәргәлиләр, иреннәрен тешлиләр һәм чытырдатып кылыч сапларын кысалар иде.

Алгы бүлмәдәгеләр Атос, Портос һәм Арамисның кабинетка чакырылуларын ишеткәннәр иде, шуңа күрә де Тревиль әфәндене́ң бик ярсыган булуын алар аның тавышыннан ук сизделәр. Унлаган кеше, кызыксынып, ишеккә колакларын куйды, эчтәгеләрнең ярсудан йөзләре агарынса, ишек ярыгына куелган колаклар андагы бер генә авазны да ычкындырмаска ты-

рыша, авызлар исә капитанның мәсхәрәле һәр сүзен кабатлап, алгы бүлмәдәгеләрнең бөтенесенә ишеттереп торалар. Бер ара бөтен йорт эче, кабинет ишеге төбеннән башлап подъездга хәтле, кайнап торган казанга әйләнеп алды.

Солдатларыныкы шикелле үк де Тревильнең дә йөрәгенә ярсуы капкан иде, шуңа күрә ул, каршындагы егетләренең күкрәкләренә хәнҗәр белән кадагандай, сүзләрен чат-чат китереп дәвам итте:

— Алай икән! Король мушкетерлары үзләрен кардинал гвардиячеләренә кулга алырга ирек куялар! Һе! Кардиналның алты гвардиячесе король хәзрәтләренең алты мушкетерын кулга ала! Нәләт яугыры! Шундый карарга килдем мин: моннан туп-туры Луврга барам да отставкага чыгаруларын сорыйм, король мушкетерлары капитаны исеменнән ваз кичеп, кардинал гвардиячеләренә лейтенант итеп куюларын сорыйм. Кире каксалар, нәләт яугыры, аббат булып китәм!

Шушы сүзләрне әйткән чакта алгы бүлмәдәге чыш-пышлар давылга әйләнеп китте. Бөтен тарафтан каргаган һәм аллага тел тидергән сүзләр яңгырады. Һавада: «Каһәр суккырылары!», «Ходай оргыры!», «Нәләт яугыры!» дигән авазлар тирбәлеп торды. Шул чагында д'Артаньян, кереп посар өчен, күзе белән берәр чаршау-мазар юкмы дип эзләде, егетнең өстәл астына кереп качасы килде.

— Болай булды ул, капитан әфәнде! — диде Портос тәмам сабырлыгын җуеп.— Без чыннан да алтыга каршы алты кеше идек, әмма алар безгә яшеренеп торып һөҗүм иттеләр, без кылычларыбызны чыгарырга да өлгермәдек, икебезне шундук кадап үтерделәр, ә Атосны бик каты яраладылар, аның хәле үлгәннән бер дә ким түгел иде; ике тапкыр аягына басарга тырышып караса да, баса алмады. Шулай да без бирелмәдек. Юк! Безне көчләп өстерәп алып киттеләр. Юлда качтык. Атоска килгәндә исә, аны үлгәнгә санап шунда калдырып киттеләр, аның белән мәшәкатьләнәсе юк дип уйладылар. Хәл менә шулай булды, капитан! Шайтан алгыры, сугышның һәммәсендә дә җиңеп булмый бит, Бөек Помпей дә Фарсаль сугышында җиңелгән, ә король Франциск Беренче,— ишетүемчә, ни җитте генә кеше булмаса да,— Павия янындагы сугышта җиңелгән.

— Минем тарафтан да мәгълүм булсын,— диде Арамис,— һөҗүм итүчеләрнең берсен мин үз кылычы белән кадап үтердем, чөнки үз кылычым беренче талпынуымда ук сынып чыкты. Үтердем дип әйтимме, чәнечтем дипме — сезгә ничек ошаса — шулай, әфәндем.

— Бу кадәресен белми идем,— диде де Тревиль әфәнде бераз йомшый төшеп.— Күрүемчә, кардинал әфәнде беркадәр күпертеп сөйләгән.

Де Тревиль әфәнденең йомшаганын күргәч, Арамисның аңа үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә батырлыгы җитте:

— Тик сездән гозерләп сорыйм, әфәндем, гозерләп сорыйм:

Атосның яраланганын беркемгә дә әйтмәгез. Бу хәл корольгә ишетелсә, Атос бөтенләй акылын җуяр. Ярасы аның бик авыр — кылыч очы, кулбашын тишеп, күкрәгенә кергән — шуңа күрә...

Шул вакытны ишектәге чаршау чите күтәрелде дә бусага төбендә чибәр, сылу йөзле, әмма хәлсезлектән чырае көл төсле агарынган бер мушкетер күренде.

Мондагы мушкетерлар икесе берьюлы:

— Атос! — дип кычкырып җибәрделәр.

Алар артыннан де Тревиль дә:

— Атос! — дип кабатлады.

— Сез мине чакыргансыз икән, капитан әфәнде,— диде Атос, де Тревильгә мөрәҗәгать итеп. Тавышы зәгыйфь булса да, бик тыныч иде үзе.— Иптәшләремнән ишетүемчә, сез мине чакыргансыз икән, шуңа күрә ашыгып килеп җиттем. Сезнең ни боерганыгызны көтәм, әфәндем!

Шулай дигәч, бик пөхтә киенгән, һәрвакыттагыча җыйнак, төз гәүдәле мушкетер нык-нык басып кабинет эченә керде. Атосның шундый зур егетлек күрсәтүенә күңеле нечкәреп, де Тревиль аның каршысына ташланды.

— Мин әле генә менә бу әфәнделәргә әйтеп тора идем: үземнең мушкетерларыма мин кирәксезгә гомерләрен куркыныч астына куюны катгый тыям. Батыр егетләр корольгә бик кирәк алар, ә мушкетерларның дөньяда иң батыр кешеләр икәне корольгә бик мәгълүм. Кулыгызны бирегез, Атос! — диде де Тревиль һәм, кабинетка килеп керүченең мондый дустанә хискә каршы җавап бирүенен дә көтмәстән, Атосның уң кулын тотып алып каты итеп кысарга кереште, Атос никадәр түзем егет булса да, ярасы сызлавына чыдый алмыйча калтыранып куюын, соң дәрәҗәдә агарынган йөзенең тагы да агара төшүен капитан сизмәде.

Кабинет ишеге яртылаш ачык калган иде. Атосның бирегә килеп чыгуына бөтен кеше шаккатты, чөнки әлеге хәлне сер итеп сакласалар да, Атосның яраланган булуы күп кешегә билгеле иде инде. Капитанның соңгы сүзләрен ишеткәч, алгы бүлмәдәге халык сөенеп шаулашып куйды, икеме-өчме кеше, исләре китеп, чаршау арасыннан башларын тыгып карадылар. Әйтергә кирәк, де Тревиль әфәнде башка чак булса мондый әдәпсезлек өчен ачуланмый калмаган булыр иде дә — шул вакыт ул Атосның тотып торган кулы дерелдәп тартышып куюын тойды һәм, мушкетерга күз салгач, егетнең аңын җуеп баруын күреп алды. Атос бөтен көчен җыеп авыртуга түзәргә тырышса да, аның инде бирешмәслек чамасы калмаган иде — шул минутта ул үлгән кеше кебек, гөрселдәп идәнгә ауды.

— Табипны китерегез! — дип кычкырды де Тревиль әфәнде.— Минем табипнымы, корольнекенме — иң яхшысын китерегез! Нәләт яугыры, табипны китереп җиткермәсәгез, минем батыр Атосым дөньядан китәчәк бит!

Алгы бүлмәгә җыелган халык де Тревиль кычкырган тавышка аның кабинетына кереп тулды. Бөтенесе яралы мушкетер тирәсендә кайнаша башладылар. Әмма табипны өеннән чакырмасалар, бөтен тырышлыклары бушка гына булачак иде. Ул халыкны ыра-ера Атос янына килде, егет исә һаман һушсыз ята иде әле. Шау-шу һәм ыгы-зыгы эшкә комачаулаганлыктан, табип иң элек яралыны күрше бүлмәгә кертергә кушты. Де Тревиль әфәнде җәһәт кенә барып ишекне ачып җибәрде дә яралы дусларын кулларына күтәреп чыгып барган Портос белән Арамиска юл күрсәтеп үзе алдан китте. Алар артыннан табип иярде, табип артыннан инде ишек ябылды.

Әнә шул чагында инде йомыш белән керүчеләрне дер калтыраткан де Тревиль әфәнденең кабинеты әллә ни арада гына алгы бүлмәнең бер өлешенә әйләнеп калды. Бөтен кеше кычкырып-кычкырып сөйләшә, усал сүз әйтүдән дә курыкмыйча, кардинал белән аның гвардиячеләрен каргый-тирги, эт итеп сүгә башладылар.

Бераздан Портос белән Арамис кабинетка кире чыктылар. Яралы янында де Тревиль белән табип кына калды.

Ниһаять, де Тревиль әфәнде дә чыкты. Аның әйтүенә караганда, Атос инде һушына килгән. Врач уенча, яралының хәле өчен дусларына әллә ни куркырлык урын юк икән, чөнки хәлсезлек күп кан югалту аркасында гына булган.

Шуннан соң, де Тревиль әфәнде кулын изәгәч, д'Артаньяннан башкалары кабинеттан чыгып киттеләр. Егет, үзенә аудиенция билгеләнгәнлеген онытмыйча, Гасконь кешеләренә хас әрсезлек белән, урынында кала бирде.

Бөтен кеше чыгып бетеп, ишек ябылгач, де Тревиль әфәнде, кире борылуга, егет белән йөзгә-йөз очрашты. Әле генә булып алган хәл аның фикер җебен чуалтып җибәргән иде. Шуңа күрә ул д'Артаньяннан нинди йомыш белән килгәнлеген сорады. Егет үзенең кем булуын әйтеп, де Тревиль әфәнденең хәтерендә узган көннәрне дә, бүгенгесен дә бик тиз яңартып җибәрде.

— Гафу итегез, кадерле якташ, мин сезне бөтенләй онытып җибәргәнмен,— диде ул көлемсерәп.— Ни телисез сез: капитан бит ул — шул ук гаилә башы, ата кеше, тик ул гади ата кешегә караганда күбрәк нәрсә өчен җаваплы. Солдатлар алар — зур балалар, әмма инде мин корольнең, бигрәк тә кардинал хәзрәтләренең боерыклары җиренә җиткерелүен таләп итә торган булгач...

Д'Артаньян елмаюын яшереп кала алмады. Аның бу көлемсерәве де Тревиль әфәндегә үз каршында акылсыз бер егет басып тормаганлыгын сиздерде, һәм шуннан соң ул туп-туры эшкә күчте.

— Сезнең атагызны бик ярата идем мин,— диде капитан.— Аның улына минем нинди ярдәмем кирәк булды икән соң? Тизрәк әйтегез, минем вакытым бетеп килә.

— Әфәндем,— дип сүзгә кереште д'Артаньян.— Тарбтан Парижга килгән чакта сезнең күңелегездә сакланган дуслык тойгыларына, сездән мушкетер плащы сорарга өметләнгән идем мин. Әмма шушы ике сәгать эчендә күргән хәлләрдән соң, мин мондый шәфкать-яхшылыкның бик зур нәрсә булачагын, минем моңа лаек була алмавым куркынычы барлыгын аңладым.

— Анысы, чыннан да, шәфкать — яхшылык ул, егетем,— диде де Тревиль әфәнде.— Әмма ул, сез уйлаганча яки уйлаган булып күренгәнчә, алай сез булдыра алмаслык эш тә түгелдер, бәлки. Хәер, король хәзрәтләренең бер боерыгында мондый очрак күздә тотып әйтелгән әйтелүен, тик мин, кызганычка каршы, сезгә шунысын әйтергә тиешмен: мушкетер булырга теләгән кешене, берничә сугышта сыналмыйча, берәр төрле искиткеч каһарманлык эшләмичә яисә безнекеннән кечерәк башка бер полкта ике ел хезмәт итмичә, мушкетерлыкка алмыйлар.

Д'Артаньян сүзсез генә баш иде, теләгенә ирешүенең никадәр авыр эш икәнлегенә төшенгәннән соң, аның мушкетер киеме киясе килүе тагы да көчәеп китте.

— Әмма,— диде де Тревиль сүзендә дәвам итеп, якташының бөтен күнел төбен күрергә теләгәндәй, егеткә үткен карашын төбәде,— әмма атагызга, әйткәнемчә, иске дустыма хөрмәт йөзеннән шулай да сезгә берәр яхшылык эшләрмен дип уйлыйм, егетем. Безнең Беарн якларында бай егетләр бик сирәк очрый торган иде, шуңа күрә мин хәзер дә туган ягымнан киткәннән бирле хәл бик нык үзгәргәндер дип уйламыйм. Алып килгән акчагыз яшәрегезгә җитәрлек түгелдер дип беләм.

Д'Артаньян, берәүдән дә хәер сорарга җыенмаганлыгын сиздереп, горур бер төс белән тураебрак басты.

— Ярый, ярый, егетем, мондый кыланышлар миңа бик таныш,— диде де Тревиль.— Мин үзем Парижга килгән чакта кесәмдә нибары дүрт экю акчам бар иде. Әгәр шунда миңа берәрсе, синең Луврны сатып алырга хәлеңнән килми дисә, мин ул кешене дуэльгә чакырырга әзер идем.

Д'Артаньян башын тагы да югарырак күтәрә төште. Ул, теге атын сату нәтиҗәсендә, үзенең карьерасын де Тревильгә караганда дүрт экюга артыграк акча белән башлап җибәрде ич.

— Димәк ки, сезнең алып килгән акчагыз никадәр күп булса да, аны сакларга кирәк,— дип сүзендә дәвам итте капитан.— Сез шулай ук корал белән эш итү осталыгын да камилләштерә төшәргә тиешсез — дворян өчен бик кирәк нәрсә анысы. Мин бүген үк Король академиясе башлыгына хат язармын, һәм ул, бернинди түләү хакы сорамыйча, сезне иртәгәдән үк кабул итәр. Бу тәкъдимнән баш тартмагыз. Безнең дворян егетләренең иң атаклы һәм иң бай дигәннәре дә еш кына бик тырышып та анда эләгә алмыйлар әле. Сез атта йөрергә, фехтованиегә, танцыга өйрәнерсез. Үзегез өчен файдалы дуслар

табарсыз, ара-тирә минем янга да килеп, эшләрегез ничек барганлыгын, миннән сезгә нинди ярдәм кирәклеген әйтеп торырсыз.

Д'Артаньян король сараендагы хәйлә, алдау шикелле нәрсәләр белән бөтенләй таныш булмаса да, шушы кабул итүдәге салкынлыкны сизми калмады.

— Их! Миңа менә хәзер әтиемнең тәкъдим хаты җитмәгәнлеген күреп торам,— дип куйды егет..

— Чыннан да, сезнең Беарн агай-энеләре өчен бик кирәкле булган әнә шул тылсымлы ачкычны алмыйча, андый ерак сәфәргә чыгып китүегез миңа бик гаҗәп тоела,— диде де Тревиль бу сүзгә каршы.

— Миндә андый хат бар иде, әфәндем, тиешенчә язылган да иде ул! Тик мәкерле адәмнәр урладылар шул аны миннән,— дияргә мәҗбүр булды д'Артаньян.

Һәм шуннан соң егет Мёңгта булган хәлләрне сөйләп бирде, таныш булмаган дворянның кыяфәтен тасвирлап күрсәтте. Аның шундый ихлас күңел белән кызып сөйләвен күреп, де Тревильнең исе китте.

— Бик гаҗәп хәл...— дип куйды капитан уйчан гына.— Димәк, сез минем исемне кычкырып әйттегез?

— Әйе шул, әйттем. Зур саксызлык күрсәткәнмен мин. Ничшлим соң инде: сезнең шикелле зур кешенең исеме минем өчен юлда бер калкан булырга тиеш иде. Шулай булгач, сезнең исемгә бик еш таянырга туры килде.

Ул заманда мактау сүзе бик модада иде, теләсә нинди король яки кардинал кебек, де Тревильнең дә мактауга күңеле эреп китә иде. Шуңа күрә ул моннан бик канәгать калып елмаеп куйды. Шулай да елмаюы бик тиз сүрелде.

— Әйтегез әле,— диде ул, Мёңгтагы хәлләргә үзе кайтып,— ул дворянның чигәсендә бераз яра эзе юк идеме?

— Әйе, пуля тигән сыман бер эз бар иде.

— Мәһабәт кенә бер ир идеме?

— Әйе.

— Озын буйлымы?

— Әйе.

— Аграк чырайлы, кара чәчлеме?

— Әйе, әйе, нәкъ үзе. Ул кешене каян беләсез, әфәндем? Их, мин аны бер эзләп тапсам,— тик ант итеп әйтәм: мин аны җәһәннәмнән булса да барыбер эзләп табачакмын...

— Берәр хатын-кызны көтә идеме ул? — дип сорады де Тревиль, егетне сүзеннән бүлдереп...

— Һәрхәлдә, үзе көтеп торган хатын белән берничә авыз сүз сөйләшкәннән соң гына китеп барды ул.

— Аларның ни сөйләшкәнен белмәдегезме?

— Хатынга бер тартма тапшырганнан соң, ул, бу тартмада минем боерыклар булыр, диде, тартманы Лондонга кайтып җиткәч кенә ачарга кушты.

— Ул хатын инглиз милләтеннән түгел идеме?

— Ул аны миледи дип атады.

— Шул үзе! — дип куйды де Тревиль пышылдап.— Шул үзе! Мин аны әле Брюссельдәдер дип уйлаган идем.

— Ай, әфәндем,— диде д'Артаньян,— әйтегезче: кем ул, каян килгән? Шуны әйтсәгез, мин сездән бүтән берни сорамас идем, хәтта мушкетер итеп алу турында да. Ник дигәндә, иң элек мин ул кешедән үчемне кайтарырга тиешмен.

— Ул эштән сезне берүк ходай саклый күрсен, егетем! — диде де Тревиль.— Сез аны урамда очратсагыз, тизрәк икенче якка чыгып китәргә тырышыгыз. Ул кыяга бәрелсәгез, пыяла урынына челпәрәмә киләрсез!

— Шулай да, мин аны очратсам...— дип куйды д'Артаньян.

— Һәрхәлдә хәзергә аны эзләргә киңәш итмим мин сезгә,— диде капитан.

Де Тревиль, күңеленә килгән сәер бер шиктән хәйран булып, кинәт тынып калды. Имештер, әтисенең хатын урлаган әлеге кешегә карата егетнең йөрәгендә ачу-нәфрәт кайный... Кем белә: бу ачу-нәфрәт дигәннең артында берәр төрле мәкер-хәйлә яшеренеп ятмый микән? Кардинал хәзрәтләренең шымчысы түгел микән бу егет? Аны, де Тревильне, берәр тозакка төшерер өчен килмәде микән бу? Үзен д'Артаньян дип атаган бу кеше шымчы түгелме, аны де Тревильнең каршына кертеп, аның ышанычын алырга да аннары, башкалар белән булган шикелле, де Тревильне харап итәргә ниятләмиләрме? Ул д'Артаньянга тагы да игътибар беләнрәк текәлеп карый башлады. Акыл, хәйләкәрлек һәм ясалма бер тыйнаклык сиздереп торган бу хәрәкәтчән йөз-кыяфәт капитанга әллә ни тынычлык китерми иде шул.

«Дөрес, мин аның Гасконь егете икәнен беләм. Әмма ул үзенең сәләтен миңа тәкъдим иткән кебек үк кардинал файдасына да җигүе ихтимал бит. Сынап карыйк...» — дип уйланды де Тревиль.

— Дустым,— дип җайлап кына сүзгә кереште ул,— мин иске дустымның улына,— чөнки хат белән булган әлеге хәлгә мин ышанам,— иске дустымның улына салкынлык күрсәтүемне акларга теләп, сезнең алда политикабызның кайбер серләрен ачам. Король белән кардинал — иң якын дуслар. Алар арасындагы чын булмаган вак-төяк каршылык ахмак бәндәләрне алдау өчен генә хезмәт итә. Бәхет-уңышлар казану өчен яратылган шундый чибәр, булдыклы бер якташ егетемнең шул фокусларның корбаны булып, бик күпләр шикелле, башын харап итүенә мин юл куя алмыйм. Шуны онытмагыз: бу кодрәтле ике галиҗәнапка мин бөтен җаным-тәнем белән бирелгәнмен һәм минем һәр адымым корольгә һәм Франция тудырган иң бөек акыл ияләренең берсе булган кардинал хәзрәтләренә хезмәт итүдән гыйбарәт. Менә шуны сез, егет, белеп торыгыз һәм әгәр дә гаилә яки дуслык багланышлары нәтиҗәсендә, я булмаса

үз тойгыларыгызга бирелеп, сез кардиналга карата, кайбер дворяннар шикелле, йөрәгегездә дошманлык хисләре саклыйсыз икән, ул чагында инде без сезнең белән бөтенләйгә саубуллашабыз. Мин сезгә нинди генә хәлләрдә ярдәм итәргә тырышсам да, сезне үземә якынайтмаячакмын. Һәрхәлдә, шушыларны ихлас күнелемнән сөйләгәннән соң, сез минем дустым булып китәрсез дип өметләнәм, чөнки моңарчы минем бер егет белән дә болай ихлас сөйләшкәнем юк иде әле.

«Әгәр бу төлкене минем янга шымчы итеп кардинал җибәргән булса, мөгаен, ул үзенең шпионына минем ышанычымны алуның иң яхшы ысулы — кардинал турында җыен әшәке сүз сөйләү дип төшендергәндер, чөнки минем аның үзен дошман күргәнемне белә ул. Әлбәттә, бу хәйләкәр хәзер, минем әлеге сүзләремә карамастан, кардинал хәзрәтләрен яратмаганлыгы, күрә алмаганлыгына мине ышандырырга тырышыр», — дип уйланды де Тревиль.

Ләкин хәл ул көткәнчә түгел, бәлки бөтенләй башкача килеп чыкты. Д'Артаньян туп-туры ярды да салды:

— Әфәндем, — диде ул гади генә итеп, — нәкъ шул теләкмаксатлар белән килдем мин Парижга. Атам миңа корольдән, кардинал хәзрәтләреннән һәм сездән башка беркемгә дә буйсынмаска киңәш итте, чөнки ул сезнең өчегезне Франциядә иң беренче кешеләр итеп саный.

Күргәнебезчә, д'Артаньян баштагы ике исемгә де Тревиль исемен дә кушып җибәрде. Аның уенча, болай кушып җибәрү зыян бозмаска тиеш иде.

— Шуңа күрә, — диде ул, — мин кардинал хәзрәтләрен бик ихтирам итәм, аның эше алдында башымны иям... Үзегез әйткәнчә, минем белән ихлас сөйләшүегез минем өчен яхшырак кына. Димәк, сез безнең карашларыбызда охшашлык күреп, миңа зур хөрмәт күрсәттегез. Әгәр инде сез миңа беркадәр шикләнеп караган булсагыз, — алай карау да бик табигый булыр иде, — ул чагында, әлбәттә, мин шушы сүзләрем белән үземне сезнең күз алдыгызда харап итәм. Әмма барыбер сез минем туры сүзле булуымны яратырсыз, ә минем өчен дөньяда иң кадерле нәрсә — сезнең минем хакта яхшы уйда булуыгыз.

Де Тревиль шаккатты. Егетнең зирәк акылы, ихласлыгы аны сокландырса да, әлеге шикне бөтенләй үк бетермәде. Бу егетнең башка егетләрдән бик күп өстенлеге күренгән саен, де Тревиль аны ихлас күңелле егет дип уйлап ялгышкан тәкъдирдә, аның белән бик сак булыр өчен нигез дә зуррак иде.

— Сез намуслы кеше, — диде де Тревиль, д'Артаньянның кулын кысып, — шулай да мин сезнең өчен әле тәкъдим иткәнемнән артыкны эшли алмыйм хәзергә. Минем йортымның ишеге сезнең өчен һәрвакыт ачык булыр. Соңрак, минем янга теләгән чагыгызда килеп йөри башлагач, димәк ки, җайлы вакытын туры китерергә мөмкинлек булгач, ихтимал, сез үзегезнең омтылган теләгегезгә дә ирешерсез.

— Икенче төрле итеп әйтсәк, әфәндем, сез минем мондый хөрмәткә лаеклы булуымны көтәсез,— дип сөйләнеп куйды д'Артаньян. Аннары Гасконь кешеләренчә үзен бик иркен тотып: «Ярый алайса, сезгә аны озак көтәргә туры килмәс»,— диде.

Шуннан соңгысы инде фәкать үзенә генә кагылышлы булган кебек, ул, китәргә җыенып, баш иде.

— Ашыкмагыз әле,— диде де Тревиль аны туктатып.— Мин сезгә академия башлыгы исеменә хат язып бирергә вәгъдә иткән идем бит. Әллә сез, егетем, артык горур булып, миннән андый хат алырга теләмисезме?

— Юк, әфәндем,— диде д'Артаньян.— Ул хат этием хаты язмышына юлыкмасын өчен сезнең каршыда мин дә аның өчен җаваплы. Мин аны бик саклап алып барырмын һәм, ант итеп әйтәм, тиешле кешесенә илтеп тапшырырмын. Аны урларга маташкан кеше соңыннан үкенеп бетә алмас!

Егетнең мондый мактанчыклыгына де Тревиль елмаймый түзмәде. Ул аны сөйләшеп торган төшләрендә — тәрәзә куышында калдырды да вәгъдә иткән хатны язарга дип өстәл янына барып утырды. Д'Артаньян бу вакытта, тик торасы килмичә, тәрәзә пыяласына нинди дер марш чиртергә кереште, йорттан бер-бер артлы чыгып китеп торган мушкетерларны күзәтте, аларны күз карашы белән урам чатына хәтле озатып торды.

Де Тревиль әфәнде хатны язып конвертка салды да аны тапшыру өчен егеткә таба килә башлады. Әмма д'Артаньян хатны алыйм дип кулын сузган мизгелдә, де Тревильне гаҗәпкә калдырып, кинәт дерт итеп сискәнеп куйды да ачу-ярсуыннан бударынып:

— Юк, нәләт төшкере! Бу юлы инде син миннән качып котыла алмассың! — дип кычкыра-кычкыра кабинеттан чабып чыга башлады.

— Кем ул? Кем? — дип сорады де Тревиль.

— Шул, шул үзе, хатны урлаучы! — диде д'Артаньян йөгерә-йөгерә. Ишектән чыгып киткәндә: — Ах, җүнсез! — дигән сүзе генә ишетелеп калды.

— Шашкан! — дип мыгырданып куйды де Тревиль. Аннары ашыкмыйча гына үз алдына сөйләнә башлады:— Әгәр дә бу... нияте барып чыкмаганлыгын аңлагач, чыгып качу өчен бер хәйлә генә булмаса...

## *IV*

## *АТОСНЫҢ КУЛБАШЫ. ПОРТОСНЫҢ ҖИЛКӘ КАЕШЫ ҺӘМ АРАМИСНЫҢ КУЛЪЯУЛЫГЫ*

Д'Артаньян, котырган шикелле, алгы бүлмәдән ике-өч кенә сикереп узды да баскыч алдына йөгереп чыкты һәм баскычтан тиз генә төшеп китәм дигән чагында, йөгереп килешли, кинәт

яп ишектән де Тревиль әфәнде катыннан чыгып килүче мушкетерга бәрелде. Мушкетер кычкырып җибәрде, дөресрәге — авыртуга түзә алмыйча үкереп җибәрде.

— Гафу итегез, гафу итегез мине, мин бик ашыгам,— диде д'Артаньян туктамаска ниятләп.

Баскыч төбенә төшеп тә җитмәде — тимер шикелле таза бер кул аны җилкә каешыннан эләктереп алды.

— Сез бик ашыгасыз икән, шул сылтау белән миңа килеп бәреләсез, гафу үтенәсез һәм шуның белән эш бетте дип санныйсызмы? — диде мушкетер, үлек төсле агарынып.— Алай түгел, егет. Бүген де Тревиль әфәнде безнең белән бик кырыс сөйләшкәч тә, сезгә дә безнең белән теләсә ничек кыланырга ярый дип уйлыйсызмы әллә сез? Юк, егет, ялгышасыз. Де Тревиль әфәнде түгел сез.

Д'Артаньян, ярасын бәйләткәннән соң өенә кайтып барган Атосны танып алып:

— Ышаныгыз сүземә,— диде,— ышаныгыз: ялгыш кына килеп чыкты бу, ялгыш килеп бәрелдем дә «гафу итегез» дидем. Минемчә, шул җиткән. Менә хәзер тагын кабатлап әйтәм — монысы инде, бәлки, артыктыр да,— мин бик ашыгам, бик каты ашыгам. Шуңа күрә сездән үтенеп сорыйм: тотмагыз мине, җибәрегез.

— Әфәндем, сез томана бер кеше икәнсез,— диде Атос, д'Артаньянның җилкә каешын җибәреп.— Ерактан килгәнлегегез әллә кайдан күренеп тора.

Д'Артаньян инде баскычның өч басмасын төшеп тә өлгергән иде — Атосның бу сүзләре аны тукталырга мәҗбүр итте.

— Нәләт төшкере, әфәндем! — дип мыгырданды ул.— Мин ерактан килгән булсам да, сезнең әдәп-инсаф өйрәтүегезгә мохтаҗ түгелмен, искәртеп куям.

— Кем белә бит! — диде Атос.

— Әх, әгәр бик ашыкмасам, бер кеше артыннан йөгермәсәм...— диде д'Артаньян.

— Алай булса, Каудар әфәнде, сез мине артымнан йөгермичә дә табарсыз, ишеттегезме?

— Кай төштә, урынын әйтмәссезме?

— Дешо монастыре янында.

— Сәгать ничәдә?

— Уникеләр тирәсендә.

— Уникеләр тирәсендә? Яхшы, шунда булырмын.

— Көттермәскә тырышыгыз. Сәгать беренче унбиш минутта килешегезгә колакларыгызны кисеп төшерәм.

— Яхшы, унике туларга ун минут кала килеп җитәрмен! — дип кычкырды д'Артаньян.

Һәм теге ят кешенең артыннан җитәргә өметләнеп, шашкан шикелле, чабып төшеп китте. Ят кеше ашыкмый гына атлый иде, әллә ни ерак китәргә тиеш түгел иде әле.

Капка төбенә җиткәч, д'Артаньян каравылчы белән сөйләшеп торган Портосны күрде. Алар, бер кеше үтеп китәрлек ара калдырып, кара-каршы басып торалар иде. Д'Артаньянга болар арасыннан узып китәргә мөмкиндер кебек тоелды. Һәм ул тиз генә үтеп китәргә чамалап, аларның ике арасына ташланды. Тик егет җил барлыгын исәпкә алып бетермәгән булып чыкты. Ул сөйләшеп торучылар арасыннан узып китәм дигәндә генә җил Портосның озын плащ итәген җәеп җибәрде дә д'Артаньян шуңа эләгеп бутала башлады. Портосның плащ итәген өздереп җибәрәсе килмәде, күрәсең, итәкне кулыннан ычкындырасы урында үзенә таба тартты, шулай итеп, д'Артаньян, Портосның киреләнүе аркасында, плащ итәге белән бергә әйләнә-әйләнә бөтенләй уралып калды.

Мушкетер әллә нинди усал сүзләр әйтеп аны сүгәргә кереште. Д'Артаньян, плащ итәге астыннан чыгарга тырышып, сукыр кеше шикелле капшана башлады. Ул барыннан да бигрәк без алда әйтеп киткән теге зиннәтле каешка зарар китермәгәем дип курка иде. Шүрли-шүрли генә күзен ачкач, ул үзенең борыны Портосның аркасына, ике калак сөяге арасына, икенче төрле итеп әйтсәк, нәкъ җилкә каешына терәлеп торганлыгын күрде.

Бу дөньядагы тыштан ялтырый торган бик күп нәрсә кебек, Портосның да зиннәтле каешы алтын булып алдан гына елкылдый икән — арттан ул гади бер буйвол күненнән тегелгән иде. Портос, чын мактанчык кешеләр шикелле, тоташ алтын укалы бау сатып ала алмагач, алдан гына алтын белән укалаганны тапкан. Салкын тидердем дию дә, плащ кию дә шул сәбәптән икән.

Мушкетер егет, плащ итәге астында кайнашкан д'Артаньяннан котылырга тырышып боргалана-боргалана:

— Ах, шайтан! — дип кычкырып җибәрде.— Акылыгыздан яздыгызмы әллә — кешеләргә ташланмасагыз!

— Гафу итегез, мин бик ашыгам. Мин бер кеше артыннан йөгерә идем...— дип мыгырданды д'Артаньян, Алып батырның култык астыннан башын чыгарып.

— Берәр кеше артыннан йөгергәндә күзегезне өйдә калдырып торасызмы әллә сез? — дип акырды Портос.

— Юк,— диде д'Артаньян хәтере калып,— юк, минем күз хәтта башкалар күрмәгәнне дә күрә әле.

Портос моны аңлагандырмы-юктырмы, әмма ачу ташы аның тәмам кызып җитте.

— Әфәндем, кисәтеп куям: әгәр дә мәгәр мушкетерларга тел тидерә торган булсагыз, тетмәгезне тетәчәкбез! — дип үкерде ул.

— Тетмәмне тетәчәксез? — дип кайтарып сорады д'Артаньян.— Катырак әйтеп ташламадыгызмы?

— Дошманнарының йөзенә туп-туры карарга өйрәнгән кеше әйтте моны.

— Шулайдыр шул! Мин бит сезнең арт ягыгызны бераүгә дә күрсәтмәскә тырышканыгызны бик яхшы беләм.

Шулай дигәннән соң егет, тапкыр сүз әйтүенә бик күңелле булып шаркылдап көлә-көлә, китеп барды.

Портос, ярсып-дулап, тегенең артыннан ташланмакчы булган иде дә, д'Артаньян аңа:

— Соңыннан, соңыннан! Плащыгызны салгач! — дип кычкырды.

— Алайса, сәгать бердә, Люксембург сарае артында!

— Бик яхшы, сәгать бердә! — дип җавап кайтарды д'Артаньян урам чатыннан борылып киткәндә.

Әмма ул чабып барган урамда да, күзенә чалынган иксенчесендә дә бер адәм заты да күренмәде. Теге ят кеше, әкрен атласа да, китеп күздән югалырга янсә берәр йортка керергә өлгергән иде инде. Д'Артаньян очраган бер кешедән аның турында сорашты, кичүгә хәтле төште, Сена урамы буйлап кире кайтып, Ал Тәре урамыннан узды. Юк, эзе дә юк иде! Шулай да әлеге кеше артыннан йөгерүнең файдасы булды аңа: маңгаена тир чыга барган саен егетнең кайнарлыгы да суына төште.

Ул булып узган хәлләр турында уйга калды. Хәлләр бик күп булды, тик берсе дә күңелле түгел иде. Вакыт әле иртәнге сәгать унбер генә, ләкин шул кыска гына арада да егет де Тревильнең ачуын китереп өлгерде, чөнки ул д'Артаньянның капыл гына кубарылып чыгып китүен әдәпсезлеккә санамый калмаячак иде.

Аннары ул берсе-берсе өч д'Артаньянны үтерерлек ике кеше белән, кыскасы — күңеленнән әллә кем итеп күргән, дөньяда иң батыр, иң көчле кешеләр дип санаган ике мушкетер белән дә сугышырга тиеш булып калды.

Әйе, хәл бик күңелледән түгел иде. Үзен Атос үтерәчәгенә тәгаен ышанганлыктан, д'Артаньян, билгеле, Портос белән сугышуы турында әллә ни борчылмады. Шулай да өмет дигәнең кеше күңелендә иң соңыннан сүнә торган бер чаткы булганлыктан, егет, бик каты яралансам да, бәлки, исән калырмын әле дип өметләнә башлады һәм әнә шуңа, киләчәктә исән калуына исәп тотып, кылган ялгышлыклары өчен үз-үзен тиргәргә кереште:

«Нинди туң баш, тупас бер кеше мин! Ул мескен Атосның нәкъ кулбашы яраланган бит, ә мин, тәкә шикелле, шуңа башым белән китереп бәрдем. Гаҗәп: ничек ул мине шундук чәнчеп үтермәде икән — үтерсә дә хаклы иде: мин аның ярасын бик яман авырттырганмындыр. Портоска килгәндә... Һи-и, Портоска килгәндә — валлаһи, анысы тагы бик мәзәк килеп чыкты бит!..»

Күңеленә әнә шундый ямьсез уйлар тулган булса да, егет көлмичә түзмәде, шулай да, бер ялгызым тиктомалга көлеп баруым кешеләргә сәер тоелмыймы дип, як-ягына каранды.

«Портоска килгәндә, анысы бик мәзәк килеп чыкты шул. Шулай да ахмак икәнмен мин. Уйлап кына кара: ярыймы инде шулай тиктомалдан кешегә бәрелеп-сугылып, аның плащы астыннан булмаган нәрсәсен күрергә тырышу?! Мин аңа әнә шул нәләт каешы турында сүз чыгарып бәйләнмәгән булсам, ул, әлбәттә, мине гафу иткән булыр иде. Дөрес анысы, мин кинаяләп кенә әйттем, шулай да ярыйсы гына киная булды ул! Аһ! Шайтан алгыры Гасконь кешесе шул мин — хәтта тамугта үземне табада кыздырганда да берәр үткен сүз кыстырырга маташырмын әле... Дустым д'Артаньян,— диде ул үз-үзенә дусларча эндәшеп,— әгәр исән калсаң (анысына ышаныч бик аз шул), моннан ары инде бик әдәпле булырга кирәк. Моннан соң бөтен кеше сиңа сокланып, синең үзеңнән үрнәк ала торган булсын. Кешегә игътибарлы һәм әдәпле булу әле ул куркак булу дигән сүз түгел. Әнә син Арамисны гына күр! Арамис ул — үзе бер йомшаклык, нәзакәтлелек өлгесе! Ә берәрсе аны куркак дип әйтә алырмы соң? Әлбәттә, юк! Моннан соң инде мин гел аннан үрнәк алачакмын. Әһә, әнә үзе дә күренә!»

Д'Артаньян, шулай сөйләнә-сөйләнә, д'Эгильоннар йорты турысына җитте һәм шунда йорт каршына туктап ике король гвардиячесе белән сөйләшеп торган Арамисны күрде. Үз тарафыннан Арамис та д'Артаньянны искәрде. Ул бүген иртән шушы егет барында де Тревиль әфәнденең бик каты кызып киткәнлеген онытмаган иде әле. Мушкетерларны ничек итеп орышуларын ишетеп торган кешене аның күңеле өнәми иде, шуңа күрә Арамис егетне күрмәмешкә салышты. Ул арада инде күңеле белән үзенең планнарына чумган, әдәп һәм игътибарлылыкта үрнәк булырга ниятләгән д'Артаньян, әлеге егетләр янына җитеп, нәзакәтле генә итеп баш иде, бик мөлаем итеп елмаеп куйды. Арамис та баш игән итсенде, ләкин елмаймады. Шунда өчесе дә сүздән тынып калдылар.

Д'Артаньян үзенең монда артык бер кеше икәнен сизмәскә ул кадәр үк ахмак егет түгел иде. Шулай да аның, таныш булмаган кешеләр янына килеп, үзенә кагылмый торган сүзгә кысылгач уңайсыз хәлдән котылу өчен югары җәмгыятьтә аралашып туплаган тәҗрибәсе юк иде. Шуңа күрә ул үзенең дәрәҗәсен төшермичә генә моннан ычкынырга җай эзләде, шул чагында Арамисның җиргә яулыгы төшүен һәм, үзе моны күрмичә, яулыкка аягы белән басуын шәйләп калды. Д'Артаньянга үзенең уңайсыз хәлдә калуын бераз йомшартырга сәбәп табылган кебек тоелды. Иелеп, бик мөлаем бер чырай белән яулыкны мушкетерның аяк астыннан тартып алды.

— Әфәндем, яулыгыгызны төшердегез, мәгез. Югалтсагыз, әрәм булыр иде,— диде егет бик әдәпле итеп.

Кулъяулыгы чыннан да бик зиннәтле итеп чигелгән, бер почмагына таҗ белән герб сурәте төшерелгән иде. Арамис кып-кызыл булып кызарынды, яулыкны Гасконь егетенең кулыннан тартып диярлек алды.

— Алай икән, алай икән, хәзер инде безнең мыштым Арамисыбыз де Буа-Траси ханым белән мөнәсәбәтләрем начар дип ышандырып маташмас безне — ул сөйкемле ханым шундый юмартлык күрсәтеп, кульяулыгын биреп торган ич! — дип куйды гвардиячеләрнең берсе.

Арамис д'Артаньянга мин синең кан дошманың булачакмын дигән мәгънәне аңлатып усал бер караш ташлады да гадәтенчә шундук шомартырга-йомшартырга кереште:

— Ялгышасыз, әфәнделәрем,— диде.— Бу яулык бөтенләй минеке түгел, бу әфәнде ни өчен аны миңа бирергә уйлагандыр — һич аңламыйм. Сүземә ышанмасагыз, менә үз яулыгымны чыгарып күрсәтәм,— дип, Арамис кесәсеннән үз яулыгын чыгарды. Бусы да бик нәфис яулык, бик юка батисттан ясалган,— ә ул елларда батист бик кыйммәт булган,— тик бернинди чигеше, гербы-мазары юк, яулык хуҗасының монограммасы гына язылган иде.

Бу юлы д'Артаньян эндәшмәде: үзенең ялгышлык эшләгәнлеген төшенде ул. Тик Арамис никадәр акланып маташса да, дуслары аның сүзенә ышанмадылар. Берсе җитди кыяфәткә кергән булып мушкетерга әйтте:

— Әш чыннан да син әйткәнчә булса, Арамис дус, ул чагында мин синнән бу яулыкны сорап алырга мәҗбүр булам. Үзеңә мәгълүм: Буа-Траси — минем бик якын дустым, шуңа күрә аның хатыны әйберсе белән кемнеңдер мактанып йөрүен теләмим мин,— диде.

— Дөрес итеп сорамыйсың син,— дип җавап кайтарды аңа Арамис.— Таләбеңне дөрес дип тапсам да, әйтелү рәвешеннән чыгып, кире кагам.

— Чыннан да, яулыкның Арамис әфәнде кесәсеннән төшкәнен күрмәдем мин,— дип курка-курка гына сүзгә кысылды д'Артаньян.— Арамис әфәнде аягы белән баскач, мин яулыкны аныкы дип уйладым.

Арамис, д'Артаньянның үз гаебен йомшартырга теләгәнлеген бөтенләй сизмәгән дә кебек, салкын гына итеп:

— Ялгышкансыз,— диде.— Карале,— диде аннары, Буа-Трасины якын дустым дигән гвардиячегә мөрәҗәгать итеп,— исеңә төшсен: минем граф де Буа-Траси белән якын дуслыгым синекеңнән бер дә ким түгел бит, дустым, шулай булгач... яулыкның минем кесәдән төшкән кебек синекеннән төшүе дә бик ихтимал.

— Юк, ант итеп әйтәм! — диде король гвардиячесе.

— Син ант итеп әйтерсең, мин валлаһи диярмен, һәм безнең беребез барыбер ялганчы булып калыр. Беләсеңме, нәрсә, Монтаран? Әйдә тотыйк та урталай бүлик без аны.

— Яулыкнымы?

— Әйе.

— Бик шәп! — дип кычкырып җибәрде гвардияче ике дус.—

Соломон хөкеме бит бу! Арамис, син чыннан да акыл капчыгы икәнсең!

Егетләр шаркылдашып көлештеләр дә эш шуның белән бетте. Берничә минуттан әңгәмә өзелде, һәм гәптәшләр чын күңелдән кул кысышып аерылыштылар. Гвардиячеләр бер якка китте, Арамис — икенче якка.

Әлеге әңгәмә дәвамында д'Артаньян бер читтәрәк басып торган иде. «Бу әйбәт кеше белән килешер өчен бик җайлы вакыт хәзер» дигән яхшы ният белән дәртләнеп, ул үзенә игътибар да итмичә китеп барган мушкетерны тизрәк куып җитәргә ашыкты.

— Әфәндем, сез мине гафу итәрсез дип өметләнәм...— дип сүз башлады д'Артаньян, мушкетерның артыннан җитеп.

— Галиҗәнап,— диде Арамис аны бүлдереп,— сезгә мәгълүм булсын: бу эштә сез намуслы кешеләрчә эш итмәдегез.

— Ничек ул алай, галиҗәнап?! — диде д'Артаньян тавышын күтәрә төшеп.— Сез ни дип уйлыйсыздыр...

— Мин болай дип уйлыйм, әфәндем: сез аңгыра егет түгел. Гасконьнан килсәгез дә, сезгә мәгълүм булырга тиеш: җиргә төшкән кулъяулыгына сәбәпсезгә басмыйлар. Париж урамнарына алай батист яулык җәеп чыкмаганнар шул әле, шайтан алгыры.

— Әфәндем, сез мине юкка кимсетәсез,— диде д'Артаньян, аның тавышында инде юашлыктан бигрәк үртәлә-кыза башлаганлыгы сизелә иде.— Мин, анысы, чыннан да, Гасконьнан килдем. Бусы инде сезгә мәгълүм булгач, Гасконь кешеләренең сабыры бик тиз төкәнә икәнлеген исегезгә төшереп тормыйм. Шулай булгач, алар берәр ахмаклык эшләп гафу үтенсәләр дә, тиешлесеннән бермә-бер артык эшләдем дигән фикердә калалар.

— Әфәндем, мин сезнең белән талашырга сылтау эзләп әйтмәдем ул сүзне. Аллага шөкер, мин андый-мондый сугыш чукмары түгелмен, мушкетерлыкта да вакытлы гына хезмәт итәм. Сугышканда да мәҗбүр булгач кына сугышам һәм бер дә сугышасым килмичә сугышам. Әмма бу юлы эш уен-муен гына түгел, сез бер ханымның абруен төшердегез — сүз шул хакта бара.

— Абруен төшергәнбез! — дип куйды д'Артаньян.

— Ничек сез ул яулыкны миңа бирә алдыгыз?

— Ә сез ул яулыкны ничек төшереп җибәрә алдыгыз соң?

— Мин бер әйткән идем инде, әфәндем, тагын бер кабатлап әйтәм: ул яулык минем кесәдән төшмәде.

— Димәк, сез, әфәндем, бер түгел, ике тапкыр алдаштыгыз, чөнки яулыкның сезнең кесәдән төшкәнлеген мин үз күзем белән күреп тордым.

— Ә-ә, сез минем белән шулай сөйләшәсезмени әле, гасконьлы әфәнде?! Ничек әдәпле булырга өйрәтермен мин сезне!

— Ә мин сезне, аббат хәзрәтләре, кире гыйбадәт кылырга кайтарып җибәрермен! Рәхим итеп, кылычыгызны чыгарыгыз, шушы минутта ук!

— Юк, юк, дустым, һәрхәлдә монда түгел. Д'Эгильоннар йорты каршында торганыбызны күрмисезмени? Бу йорт кардиналның ялчылары белән тулган. Кардинал хәзрәтләре сезгә минем башны китереп бирергә кушмаган дип кем ышандыра ала мине? Беләсезме, ни хикмәттер, минем башым үземә дә бик кадерле. Үз урынында бик яхшы тора дип уйлыйм мин аны. Шуңа күрә бер дә борчылмагыз, мин сезне үтерергә риза, тик шау-шусыз гына, аулак бер җирдә, сез үлемегез белән беркемгә дә мактана алмаслык төштә.

— Ярый, шулай булсын. Тик берүк үз-үзегезгә артык ышанып куймагыз, кульяулыгыгызны да алып барыгыз: үзегезнекеме ул, түгелме, барыбер аның сезгә кирәк булуы бар.

— Сез Гасконь кешесеме, әфәндем? — дип ирония белән сорады Арамис.

— Әйе. Гасконь кешеләре гадәттә сугышуны саклык йөзеннән икенче вакытка калдырмыйлар.

— Саклык ул мушкетерларга хас сыйфат түгел, әфәндем, мин аны беләм. Чиркәү әһелләренә кирәкле сыйфат ул. Мин үзем вакытлыча гына мушкетер булып йөргәнлектән, сак булуны яхшырак күрәм. Мин сезнең белән сәгать икедә де Тревиль әфәнде йортында очрашырмын. Шунда мин сезгә сугышыр өчен яраклы урынны әйтермен.

Егетләр бер-берсенә баш иделәр дә, Арамис Люксембург сараена бара торган урам буйлап китте, д'Артаньян исә, вакытның инде соң булуын чамалап, Дешо монастыре ягына таба атлады.

«Берни дә эшләп булмый инде, хәл төзәтүдән узган. Тик бер генә юанычым бар: үлсәм дә, мушкетер кулыннан дөньядан кичәм», — дип үз алдына уйланды егет.

## V

## КОРОЛЬ МУШКЕТЕРЛАРЫ ҺӘМ КАРДИНАЛ ХӘЗРӘТЛӘРЕ ГВАРДИЯЧЕЛӘРЕ

Парижда д'Артаньянның бер танышы да юк иде. Шуңа күрә ул Атос белән сугышырга, дошманының секундантларына гына риза булып, үзе секундантсыз китте. Хәер, ул алдан ук, үзенең йомшаклыгын сиздермичә генә, батыр мушкетердан гафу үтенергә дип күңеленә беркетеп куйган иде. Яшь таза кеше яралы, хәлсез дошманы белән сугышканда нәтиҗәсе бик авыр булу ихтималын күздә тотып уйлаган иде ул шулай. Әгәр ул җиңелсә, дошманы бик каты сөенәчәк, әгәр инде ул җиңсә — аны намуссызлыкта гаепләячәкләр, уңышка бик җиңел иреште, дип әйтәчәкләр.

Хәер, мажара эзләүче егетебезнең характерын без я начар тасвирлаганбыз, я д'Артаньянның гадәти бер кеше түгеллеген укучы чамалап өлгермәгәндер әле. Шуңа күрә егет үз-үзенә «үлүем котылгысыз» дип тәкрарласа да, кыюсызрак, сәләтсезрәк икенче бер кеше кебек, бу котылгысызлыкка берсүзсез буйсынырга уйламады. Ул сугышасы кешеләренең холык аерымлыкларын күз алдына китерергә тырышты һәм шулай итеп хәл әкренләп ачыклана төште. Атосның кырыс йөзе белән мәһабәт буй-сыны д'Артаньянга бик ошаган иде, шуңа күрә аңардан гафу үтенгәч, бәлки, дуслашып та китәрбез, дип өметләнә иде. Портосны ул «теге зиннәтле каешыгыз хакында әйтәм» дип куркытмакчы була, чөнки д'Артаньян, шунда үлеп калмаса, әлеге нәрсәне бөтен кешегә сөйли алачак, ә инде җаен һәм рәвешен китереп сөйләгәндә бу сүз Портосны дуслары белән иптәшләре каршында көлкегә калдыруы ихтимал иде. Хәйләкәр Арамиска килгәндә исә, д'Артаньянның аңа әллә ни исе китмәде. Чират аңа да җиткән тәкъдирдә д'Артаньян аны үтерергә яки, Цезарь Помпей солдатлары белән ничек эш итәргә кирәклегенә өйрәткән кебек, Арамисның битенә кадап, аның мактанычы булган йөз сылулыгына зыян китерергә дип күңеленә беркетеп куйды.

Моннан тыш, д'Артаньянның әтисе киңәше белән туган, «Корольдән, кардиналдан һәм де Тревиль әфәндедән башка беркемгә буйсынмаска» дигән катгый карары да бар бит әле. Шуңа күрә д'Артаньян Дешо монастыреңа таба атлап кына түгел, очып диярлек барды. Монастырь дигәнебез тәрәзә пыялалары ватылып беткән ташландык бер йорт, тирә-ягында берни үсми, кирәк чагында Пре-о-Клерк хезмәтен үти торган буш бер ялан: вакыты бик кадерле кешеләр гадәттә шунда барып сугышалар иде.

Д'Артаньян монастырь янындагы яланга килеп җиткәндә сәгать уникене сукты. Атос аны нибары биш кенә минут көткән — димәк, д'Артаньян вакытында килеп җиткән, дуэль законнары белән эш итүче иң таләпчән судья да бу очракта сүз әйтә алмас иде аңа.

Де Тревиль табибы Атосның кулбашын яңадан бәйләсә дә (аның ярасы бик авырта иде әле), ул гадәтенчә сабыр гына, егетләрчә горур бер кыяфәт белән таш өстендә дошманын көтеп утыра иде. Д'Артаньянны күрү белән урыныннан торды да әдәп йөзеннән берничә адым аңа каршы килде. Д'Артаньян да үз нәүбәтендә эшләпә каурыен җирдән үк сөйрәтеп дошманына таба якынлашты.

— Әфәндем,— диде Атос,— мин секундантларым булырга тиешле ике дустымны чакыртып кеше җибәргән идем. Тик ул дуслар килеп җитмәделәр әле. Аларның соңга калулары бик сәер: андый гадәтләре юк иде.

— Минем секундантларым юк,— диде д'Артаньян.— Мин Парижга әле кичә генә килдем, шуңа күрә де Тревиль әфәнде-

дән башка монда бер танышым да юк. Минем әти заманында аның дусты булган, ул мине де Тревиль әфәндегә тәкъдим итеп җибәргән иде.

Атос беравыкка уйга калды.

— Сез нибары де Тревиль әфәнде белән генә танышмыни? — дип сорады аннары.

— Әйе, әфәндем, мин аның белән генә таныш шул.

— Менә сиңа хикмәт! — дип куйды Атос, үз-үзенә дә, әңгәмәдәшенә дә әйткән сыман итеп.— Менә сиңа хикмәт! Әгәр мин сезне үтерсәм, бала-чага җанын кыючы дигән яман атым таралмас микән соң?!

— Алай түгел, әфәндем,— дип, д'Артаньян горур гына кыяфәт белән баш иеп алды.— Алай түгел, сез үзегез, ярагызның авыртуына карамастан, минем белән сугышырга риза булып, миңа зур ихтирам күрсәтәсез.

— Ярам бик авырта, валлаһи. Турысын әйтим, бик яман авырттырдыгыз ярамны. Тик мин, мондый очрактагы гадәтемчә, кылычны сул кулыма тотачакмын. Әмма, моңа карап, үзегезгә җиңелрәк булыр дип уйламагыз: мин ике кулым белән дә иркен эш итәм. Алай сезгә беркадәр җайсызрак та булачак әле. Сулагай кеше шул җайга сугышырга хәзерләнмәгән дошманы өчен бик уңайсыз ул. Бу хакта сезгә алдан әйтеп куймавым өчен гафу үтенәм.

— Сез, әфәндем, ифрат та ихтирамлы кеше икәнсез, моның өчен сезгә чын күңелемнән рәхмәтемне белдерәм,— дип сөйләнде д'Артаньян.

— Сезнең мондый сүзләрегез, ихластыр, мине беркадәр аптырашта калдыра,— диде Атос нәзакәтле бер әдәплелек белән.— Әгәр сез каршы булмасагыз, башка нәрсәләр хакында сөйләшик... Ах, шайтан, ярамны шундый авырттырдыгыз! Кулбашым ут кебек яна!

Д'Артаньян кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Әгәр сез рөхсәт итсәгез...

— Нәрсә рөхсәт итсәм, әфәндем?

— Миндә яра дәвалый торган бик шифалы бәлзәм бар. Ул бәлзәмне миңа әнием биреп җибәргән иде. Мин аны үземдә сынап карадым.

— Нинди нәрсә соң ул?

— Нинди нәрсә булсын: ике-өч көн эчендә сезне — чын әгәр — тап-таза кеше итәчәк, ә өч көннән соң инде, сез сәламәтләнгәч, әфәндем, сезнең белән кылычта көч сынашуны үзем өчен зур бәхет дип санар идем.

Д'Артаньян бу сүзләрне үзен ихтирамлы бер кеше итеп күрсәтә торган гадилек белән һәм шул ук вакытта батырлыгына шикләнергә урын калмаслык итеп әйтте.

— Валлаһи, дим, әфәндем, мондый тәкъдимегез миңа бик ошый,— диде Атос.— Минем моңа риза булуымнан түгел, бәлки бу тәкъдимнән дворяннарча намуслылык сизелеп тора. Бөек

Карл заманы гаскәриләре әнә шулай сөйләшкәннәр һәм шул рәвешчә эшләгәннәр. Һәрбер кавалер алардан үрнәк алырга тиеш. Ләкин без, кызганычка каршы, бөек император заманында яшәмибез шул. Без мөхтәрәм кардинал хәзрәтләре заманында яшибез, һәм өч көн эчендә без бу серебезне никадәр генә яшерергә тырышсак та, безнең сугышырга җыенуыбыз башкаларга билгеле булачак һәм безгә ниятебезне тормышка ашырырга комачау итәчәкләр. Һе, бу ялкаулар бөтенләй юкка чыкканнар, ахры!

Д'Артаньян бая дуэльне өч көнгә чигереп торырга дип тәкъдим иткәндәге кебек гади генә әйтеп куйды:

— Әгәр, әфәндем, бик ашыгасыз икән һәм минем белән эшне хәзер үк бетерәсегез килә икән, ул чагында рәхим итегез — уңайсызланып тормагыз.

— Бу сүзегез дә бик ошый миңа,— диде Атос д'Артаньянга якты чырай белән баш кагып.— Акыллы һәм, һичшиксез, саф намуслы кеше сүзе бу. Әфәндем, сезнең кебек кешеләрне мин бик яратамын һәм белеп торам: әгәр дә без бер-беребезне үтерешмәсәк, соңыннан миңа сезнең белән әңгәмәдәш булу бик зур канәгатьлек тудырыр иде. Үтенеп сорыйм, дусларымны бераз көтик инде, минем беркая да ашыгасым юк, аннары алай әдәплерәк тә булыр. Әһә, әнә берсе килә бугай!

Чыннан да, Вожирар урамы башында шул минутта алыптай гәүдәле Портос күренде.

— Ничек ул алай? Сезнең беренче секундантыгыз — Портос әфәндемени? — дип гаҗәпләнеп сорады д'Артаньян.

— Әйе. Әллә ул сезгә берәр ничек ошамыймы?

— Юк, юк!

— Әнә икенчесе дә килә.

Д'Артаньян, Атос күрсәткән якка борылып карауга, Арамисны танып алды.

— Ничек ул алай? — диде егет баягыдан да битрәк гаҗәпләнә төшеп Сезнең икенче седундантыгыз — Арамис әфәндемени?

— Әлбәттә. Сез белмисезмени: без бит беркайчан да берберебездән башка йөрмибез, мушкетерлар арасында да, гвардиячеләр дә, король сараенда да һәм калада да безне Атос, Портос һәм Арамис дип яки аерылгысыз өч дус дип кенә атыйлар. Хәер, сез Дакстанмы, Подамы килгән булгач...

— Тарбтан,— дип төзәтеп куйды д'Артаньян.

— ...андый нечкәлекләрне белеп бетермәвегез дә гаеп түгел.

— Валлаһи, сезгә кушкан исем, хөрмәтле әфәнделәр, бик уңышлы, менә минем белән булган бу хәл, әгәр кешеләргә ишетелсә, сезнең дуслыкның характерлар аерымлыгына түгел, бәлки аларның охшашлыгына нигезләнгәнлегенә бер дәлил булачак,— дип сөйләнде д' Артаньян.

Ул арада Портос, якынрак килеп, кул изәп кенә Атосны

сәламләде, аннары, борылып карагач, д'Артаньянны танып, aптырый калды.

Сүз арасында гына шуны да әйтеп китик: Портос инде теге вакыттан бирле җилкә каешын алмаштырып, плащын салырга өлгергән иде.

— Ала-ай икән...— дип сузып кына әйтеп куйды ул.— Бу ни дигән сүз була соң әле?

— Менә шушы әфәнде белән сугышам мин,— диде Атос, д'Артаньянны сәламләгән шикелле, кулын аңа таба изәп.

— Мин дә аның белән сугышам ич,— диде Портос.

— Сезнең белән көндезге бердә бит әле,— диде Гасконь егете сабыр гына.

Ул арада болар янына Арамис та килеп җитеп:

— Мин дә шушы әфәнде белән сугышам,— дип белдерде.

— Сезнең белән сәгать икедә,— диде д'Артаньян һаман сабыр гына.

— Атос, син нинди сәбәп аркасында сугышасың? — дип сорады Арамис.

— Валлаһи, әйтергә дә уңайсыз,— диде Атос.— Кулбашыма бәрелеп ярамны авырттырды ул. Ә син, Портос?

— Мин сугышу өчен генә сугышам,— диде Портос кызарынып.

Үткен күзле Атос Гасконь егетенең сизелер-сизелмәс кенә елмаюын күреп калды.

— Без кием хакында бәхәсләшеп киткән идек,— диде егет.

— Ә син, Арамис?

Арамис д'Артаньянга дуэльнең чын сәбәбен әйтмә дигән мәгънәдә ым какты да:

— Мин бер дини мәсьәлә буенча килешмәгәнлектән сугышам,— дип җавап кайтарды.

Атос Гасконь егетенең тагын көлемсерәвен күреп калды.

— Чынлапмы? — дип кайтарып сорады Атос.

— Әйе, изге Аугустиндагы бер сүрә мәсьәләсендә безнең фикерләребез туры килмәде,— диде д'Артаньян.

«Һичшиксез, акыллы егет бу»,— дип уйлап куйды Атос.

— Ә хәзер инде, хөрмәтле әфәнделәр, бөтенегез дә җыелып беткәч, миңа сездән гафу сорарга рөхсәт итегез,— диде д'Артаньян.

«Гафу» сүзен ишетүгә, Атосның чырае сүрелеп китте, Портос мыскыллы гына бер төстә көлемсерәп куйды, ә Арамис өнәмичә башын чайкады.

— Сез мине аңлап җиткермәдегез, әфәнделәр,— диде д'Артаньян, башын күтәреп. Шул минутта аның башына кояш яктысы төшеп, егетнең нәфис һәм кыю йөз чалымнарын ачыграк итеп күрсәтте.— Мин сезнең өчегезгә дә канәгатьлек бирә алмау ихтималын күздә тотып гафу сорадым. Үзегезгә мәгълүм: Атос әфәндענең мине беренче булып үтерә алу хокукы бар, әнә шул сәбәпле минем сезгә тиешле егетлек бурычымны

түли алмавым ихтималы бар, Портос әфәнде. Ул чагында инде сезгә дигән бурычым, Арамис әфәнде, буш сүз генә булып калачак. Ә хәзер, галиҗәнаплар, тагын бер тапкыр кабатлап әйтәм: мине гафу итүегезне сорыйм, тик моның өчен... Башлыйбызмы?

Шулай дигәч, Гасконь егете гайрәт белән кылычын кынысыннан суырып чыгарды.

Башына шаулап кан йөгерде. Бу минутта ул, Атос, Портос һәм Арамиска каршы кылычын суырып чыгарган кебек үк, бөтен король мушкетерларына каршы торырга да әзер иде.

Сәгать беренче унбиш минут иде. Кояш нәкъ баш түбәсенә менеп җиткән һәм дуэль буласы урынга ут шикелле кайнар нурларын сибә иде.

— Эссе,— диде Атос, үз нәүбәтендә кылычын чыгарып.— Шулай булса да, миңа камзулымны салырга ярамый. Ярамнан кан саркыганны сизеп торам, үзе агызмаган канны күреп, дошманым аптырап калмагае дип куркам.

— Шулай, әфәндем,— диде д'Артаньян.— Тик ул канның агуына мин үземме яки башка берәүме сәбәпче булса да, ихластан әйтәм, шундый батыр дворянның канын күрү минем йөрәгемә һәрвакыт авыр булачак. Мин дә, сезнең шикелле, камзулымны салмыйча сугышам.

— Анысы бик шәп, тик төчеләнүне туктатырга вакыт! Безнең дә чират көткәнебезне онытмагыз,— диде Портос.

— Андый ахмак сүзләрне үз исемегездән генә әйтегез, Портос,— диде Арамис.— Миңа калса, бу ике әфәнденең сүзләре бик әйбәт һәм саф намуслы ике дворянга бик лаек.

— Рәхим итегез, әфәндем, мин әзер,— дип, Атос үзенең урынына басты.

— Бу сүзегезне көтеп кенә тора идем,— диде д'Артаньян, кылычын Атос кылычына аркылы куеп.

Ләкин кылычлар бер-берсенә тиеп чыңларга да өлгермәде — монастырь чатыннан де Жюссак әфәнде командалыгында кардинал гвардиячеләре отряды күренде.

— Кардинал гвардиячеләре килә! — дип Портос белән Арамис икесе бертавыштан кычкырып җибәрделәр.— Кылычларыгызны җыегыз, әфәнделәр! Кылычларыгызны җыегыз!

Әмма эш узган иде инде. Тегеләр ике дуэльчене нинди ният белән кара-каршы басканлыкларын белгертеп торган позада күреп калганнар иде.

— Әй! — дип кычкырды де Жюссак аларга таба атлап, егетләренә үз артыннан иярергә ымлады.— Әй, мушкетерлар! Сугышырга җыендыгызмы сез? Эдиктларны оныттыгызмыни?

— Артык илтифатлы сез, гвардияче әфәнделәр,— диде Атос ачуы килеп, чөнки де Жюссак моннан ике генә көн элек булган һөҗүмгә катнашучы бер кеше иде.— Әгәр без сезнең сугышып ятканыгызны күрсәк, ихлас, сезгә комачауламас

идек. Сез безгә ирек бирегез дә, хезмәт куймыйча гына, зур канәгатьлек алырсыз.

— Галиҗәнаплар,— диде де Җюссак,— кызганычка каршы, мин сезгә андый эшнең мөмкин түгеллеген әйтергә мәҗбүрмен. Хезмәт вазифабыз — беренче бурычыбыз ул безнең. Кылычларыгызны җыеп куегыз да безнең арттан иярегез.

— Галиҗәнап,— диде Арамис де Җюссакны үртәп,— без сезнең бу матур тәкъдимегезгә рәхәтләнеп риза булыр идек тә, бездән генә тормый шул ул. Бәхетсезлеккә каршы, ул эш мөмкин түгел: де Тревиль әфәнде безгә тыйды шул андый эшне. Үз юлыгыз белән генә китегез инде — сезнең өчен шуннан да яхшысы булмас.

Арамисның мыскыллы сүзләре де Җюссакның җен ачуларын чыгарды.

— Буйсынмасагыз, без сезгә һөҗүм итәбез! — диде ул.

— Алар бишәү, ә без өчәү генә,— диде акрынрак тавыш белән Атос.— Без тагын җиңеләчәкбез, яки шушында үлеп калырга туры киләчәк, чөнки, әйтеп куям: җиңелсәк, мин капитанның күзенә күренмәячәкмен.

Атос, Портос һәм Арамис шундук бер төшкәрәк тупландылар, ә де Җюссак ашыга-ашыга үз солдатларын тезде.

Шушы минут та д'Артаньянга җитә калды: ул анык бер карарга килде. Кешенең язмышын хәл итә торган бер ара булды бу. Егеткә я король ягын, я кардинал тарафын сайларга кирәк һәм, сайлагач инде, шул тарафны якларга тиеш булачак иде. Сугышка катнашу — законга буйсынмау, җаныңны кыл өстенә кую, корольнең үзеннән дә кодрәтлерәк министрның дошманы булу дигән сүз иде. Егет боларның бөтенесен бер мизгел эчендә төшенеп алды. Һәм аны мактап әйтергә тиешбез: ул бер генә секундка да икеләнеп калмады.

— Әфәнделәр,— диде ул Атос белән аның дусларына,— минем өстемдә мушкетер киеме булмаса да, рухым-җаным белән мушкетер мин. Минем йөрәгем — мушкетер йөрәге. Мин шулай дип хис кылам һәм мушкетер буларак эш итәм.

Д'Артаньянның чырайен һәм кул хәрәкәтләрен күреп, де Җюссак аның ниятен аңлап алды булса кирәк:

— Читкәрәк китегез, егет! Бөтенләй китсәгез дә була, без каршы түгел. Үз җаныгызны саклагыз! Тиз булыгыз! — дип кычкырды.

Д'Артаньян урыныннан селкенмәде дә.

— Сез чыннан да батыр егет икәнсез,— диде Атос, егетнең кулын кысып.

— Тизрәк, тизрәк хәл итегез! — дип кычкырды де Җюссак.

— Тизрәк булыйк, нинди дер чара кылырга кирәк бит,— диделәр Портос белән Арамис.

— Олы җанлы бер егет икән бу,— диде Атос.

Ләкин аларның өчесен дә д'Артаньянның яшь, тәҗрибәсез булуы борчый иде.

— Без өчәү булабыз, шуннан беребез яралы; сабый дип әйтерлек бер малай килеп кушылса, безне дүртәү иде дип әйтәчәкләр.

— Анысы шулай, әмма куркып кире чигенү!..— дип куйды Портос.

— Мөмкин түгел,— диде Атос.

Д'Артаньян боларның икеләнеп торуының сәбәбен аңлап алды.

— Галиҗәнаплар,— диде ул,— сез иң элек мине сынап карагыз. Ант итеп әйтәм: әгәр без җиңелсәк, мин шушы җирдән китмим, шушында ятып калам.

— Исемегез ничек, батыр егет? — дип сорады Атос.

— Д'Артаньян, әфәндем.

— Димәк: Атос, Портос, Арамис, д'Артаньян! Кузгалдык! — дип кычкырды Атос.

— Ягез, әфәнделәрем, хәл кылдыгызмы инде, юкмы? — дип сорады де Жюссак.

— Хәл кылдык, әфәндем,— диде Атос.

— Ничек хәл кылдыгыз? — дип сорады де Жюссак.

Арамис, бер кулы белән эшләпәсен күтәрә төшеп, икенчесе белән кылычын чыгарып:

— Без, хөрмәтлем, сезгә һөҗүм итәбез,— диде.

— Шулаймыни, сез каршы тормакчы буласызмы? — дип кычкырып куйды де Жюссак.

— Нәләт төшкере! Сезгә гаҗәп тоеламыни?

Шуннан соң инде кара-каршы сугышучы тугыз кеше ярсып-кызып бер-берсенә ташландылар, хәер, аларның хәрәкәтендә акыл белән уйлап эш итү дигән нәрсә дә юк түгел иде.

Атос кардиналның яраткан солдаты Каюзак белән сугыша башлады, Портоска Бикара туры килде, Арамис исә берьюлы ике дошман белән йөзгә-йөз очрашты.

Д'Артаньянга дошман булып де Жюссак үзе туры килде.

Гасконь егетенең йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгардай булып тибәргә кереште. Куркудан түгел — анда курку дигәннең әсәре дә юк иде — ярсыганнан шулай тибә иде егетнең йөрәге. Ул тактикасын һәм урынын туктаусыз алмаштыра-алмаштыра, дошманы тирәсендә бөтерелеп, ярсу юлбарыс кебек сугыша иде. Жюссак исә, ул замандагыча әйткәндә, «кылыч остасы» иде, өстәвенә зур тәҗрибәсе дә бар иде. Шуңа да карамастан, ул җитез, чая дошманына көчкә-көчкә генә каршы тора, егет исә минут саен гадәттәге кагыйдәләрне бозып, әле бер яктан, әле икенче яктан һөҗүм итә һәм шул ук вакытта, үзенең тәнен бик тырышып саклаучы кеше шикелле, дошманының кылычын кире кайтарып тора иде.

Ахыр чиктә де Жюссак мондый көрәшкә түзмәде. Үсмер бер малай дип санаган дошманын җиңә алмавына бик яман гарьләнеп кызып китте, ялгышлык артыннан ялгышлык ясый башлады. Зур тәҗрибәсе булмаса да, теорияне хәтерләгән

д'Артаньян хәрәкәт тизлеген бермә-бер арттырды. Жюссак, бик каты кадап дошманын үтермәкче булып, капыл гына алга талпынды. Әмма д'Артаньян аның кылычын ялт кына кире сугып җибәрде дә, Жюссак тураюга, елан шикелле аның култык астыннан шуып чыгып, дошманын кылыч белән аркылы тиште. Жюссак гөрселдәп җиргә ауды.

Д'Артаньян, дошманыннан арынгач, борчулы бер төс белән тиз-тиз генә сугыш мәйданына күз йөртеп чыкты.

Арамис инде бер дошманын кадап еккан, ләкин икенчесе аны бик нык кысрыклап ята иде. Шулай да Арамисның хәле ярыйсы, ул әле дошманына каршы тора алырлык иде.

Бикара белән Портос кылычларын ялт-йолт китереп сугышып яталар. Портосның беләге, Бикараның боты яраланган. Тегесенең дә, бусының да ярасы ул хәтле куркыныч түгел иде, шуңа күрә алар, тагы да кыза төшеп, кылыч уйнату осталыгын күрсәтергә керештеләр.

Атос, икенче тапкыр Каюзак тарафыннан яраланып, чырае агарганнан-агара барса да, бер адым да артка чигенми иде әле. Тик ул хәзер кылычын икенче кулына күчереп, сул кулы белән сугыша башлаган иде.

Ул замандагы дуэль законнары буенча, д'Артаньянның сугышучыларның берәрсенә ярдәм итәргә дә хакы бар иде. Кайсысына ярдәм кирәгрәк икән дип аптырап торганда ул кинәт Атосның күз карашын күреп алды. Кызганыч та һәм гаҗәп гыйбрәтле дә иде бу караш. Атос үлсә үләр, әмма ярдәмгә кеше чакырмас. Аның болай гына каравы да, карашы белән ярдәм соравы да мөмкин. Д'Артаньян, шуны аңлап, янән Каюзакка ташланды.

— Миңа таба борылыгыз, гвардияче әфәнде! Мин сезне үтерәм!

Каюзак аңа таба борылды. Атоска ярдәм бик вакытлы килеп җитте. Коточкыч чыдамлыгы белән генә бирешмичә түзеп торган мушкетер бер аягына тезләнде.

— Нәләт төшкере! — дип кычкырды ул.— Үтермәгез аны, егет. Минем, сәламәтләнеп җиткәч, иске үтечемне кайтарасым бар. Коралсызландырыгыз, кылычын бәреп төшерегез... Әнә шулай... Бик шәп! Бик шәп!

Каюзакның кылычы егерме адымнар чамасы читкә очып киткәнен күргәч, Атос шулай дип кычкырды. Д'Артаньян белән Каюзак икесе берьюлы кылычка ташландылар: берсе — кылычсыз калмас өчен, икенчесе — аны дошманы кулына тоттырмас өчен. Д'Артаньян җитезрәк булып чыкты — иң алдан барып җитеп, кылычның йөзенә аягы белән басты.

Каюзак Арамис үтергән гвардияче янына йөгереп барып, аның рапирасын алды да кире д'Артаньян янына кайта башлады, ләкин кире килгәндә хәл алып өлгергән Атоска юлыкты. Д'Артаньян дошманымны үтереп куймагае дип, Атос яңадан сугыша башларга ниятли иде.

Атоска комачаулау аның күңелен рәнҗетү булачагын аңлады д'Артаньян. Һәм чыннан да берничә секунд үтүгә, Каюзак җиргә ауды — Атосның кылычы аның бугазына кадалган иде.

Бу вакытта Арамис та кылыч очын җирдә яткан дошманының күкрәгенә терәп, аны җиңелдем дип әйтергә мәҗбүр итте.

Хәзер инде Портос белән Бикара гына калды. Портос, кылтаеп, Бикарадан: «Синеңчә, хәзер сәгать ничәләр булыр?» — дип сорый, аны Наварра полкында абыйсы алган рота белән тәбрик иткән була. Ләкин болай мыскыллауларының бернинди файдасы юк. Бикара үлгәндә генә егыла торган тимер кебек таза кешеләрнең берсе иде.

Шулай да сугышны бетерергә вакыт иде инде. Менә хәзер сакчылар килеп чыгып, дуэльгә катнашучыларның барысын да — исән калганнарын да, яралыларны да, роялистларны да, кардиналистларны да кулга алулары ихтимал иде. Атос, Арамис һәм д'Артаньян, Бикараны чолгап алып, аңа бирелергә куштылар. Боты яраланган Бикара, дүрт кешегә каршы бер үзе булса да, бирелүдән баш тартты. Шул вакыт де Җюссак терсәгенә таянып калкына төште дә Бикарага: «Бирел!» — дип кычкырды. Бикара да, д'Артаньян кебек, Гасконь егете иде. Башлыгының кушканына исе дә китмәде, көлемсерәп кенә куйды. Сугышуында дәвам итеп, артка кайшалган бер арада кылыч очы белән җиргә төртеп күрсәтте дә Тәүрат китабы сүзләрен китергән булып:

— Биредә, биредә җан бирәчәк Бикара, һәм аның белән бергә булганнарның берсе,— диде.

— Алар синең бер үзеңә каршы дүртәү бит. Боерып әйтәм мин сиңа: бирел!

— Син боерып әйткәч, башка эш,— диде Бикара.— Син минем бригадир, шулай булгач, мин сиңа буйсынырга тиешмен.

Һәм ул капыл гына артка чигенде дә кылычын дошманына бирмәс өчен шартлатып урталай сындырды. Кылыч сыныкларын монастырь стенасы аша ташлагач, кулларын күкрәгенә кушырды даниндидер кардиналистлар җырын сызгыргаларга керешге.

Батырлык, дошманың батырлыгы булса да, һәрвакыт ихтирам уята. Мушкетерлар кылычларын күтәреп батыр гвардиячегә салют бирделәр дә кынысларына салып куйдылар. Боларга ияреп д'Артаньян да нәкъ шулай эшләде, аннары, гвардиячеләр арасында аягында басып калган бердәнбер исән кеше Бикара белән икәү, Җюссакны, Каюзакны, Арамисның яраланган бер дошманын монастырь баскычы янына илтеп яткырдылар. Дүртенче гвардияче, әйткәнебезчә, үлгән иде. Шуннан соң, монастырь ишеге төбендәге чаңны чалтыраттылар да, биш кылычның дүртесен алып, шатлыклары һушларына киткән бер хәлдә, де Тревиль әфәнде йортына таба юл тоттылар.

Бер-берсе белән култыклашып, бөтен урамны иңләп, очраган бер мушкетер белән сөйләшә-сөйләшә атладылар алар,

шулай итеп аларның бу рәвешчә кайтулары җиңүчеләр кайтуына охшап калды. Д'Артаньянның инде күңеле җиде кат күкләрдә гизә иде. Ул, Атос белән Портосны кочаклап, алар уртасында атлады.

Де Тревиль йортының ишеге төбенә кайтып җиткәч, яңа дусларына мөрәҗәгать итеп ул болай диде:

— Хәзергә мушкетер булмасам да, мин үземне өйрәнчеклеккә алынган дип саный алам инде, шулай бит? — диде.

## VI

## КОРОЛЬ ХӘЗРӘТЛӘРЕ ЛЮДОВИК УНӨЧЕНЧЕ

Әлеге вакыйганың шау-шуы шактый зур булды. Де Тревиль әфәнде тыштан үзенең мушкетерларын сүксә дә, эчтән аларны тәбрик итә иде. Әмма вакытны әрәм итәргә ярамый: корольне хәзер үк искәртеп куярга кирәк иде, шуңа күрә де Тревиль әфәнде ашыгып Луврга китте. Ләкин соңга калган булып чыкты: король кардинал белән, биклөнеп утыра иде. Де Тревильгә: король буш түгел, хәзер беркемне дә кабул итә алмый, диделәр. Шуннан соң де Тревиль кич белән, король карта уйнаган чакта килде. Корольнең усны отышлы иде, һәм бик саран кеше булганлыктан, отыштан аның кәефе дә күтәрелеп киткән иде.

— Бирегә килегез әле, капитан әфәнде! — дип кычкырды король де Тревильне ерактан ук күреп алып.— Килегез әле, бик әйбәтләп кенә бер сүгим әле үзегезне. Сезгә мәгълүм микән: кардинал хәзрәтләре миңа килеп сезнең мушкетерларыгыздан зарланды, шулкадәр каты борчылды — минем белән сөйләшкәннән соң хәтта урынга ятарга мәҗбүр булды. Ниткән хәл бу — башкисәрләрме әллә ул сезнең шайтан алгыры мушкетерларыгыз?

— Юк, галиҗәнап,— диде де Тревиль, эшнең кая таба барганын беренче сүздән үк төшенеп алып.— Түгел, нәкъ киресенчә әле: алар сарык шикелле юаш, мәхлук бер җан ияләре, аларның бөтен омтылышы кылычларын сез галиҗәнап файдасына хезмәт иттерү генә, ихластыр шулай. Инде нишләмәк кирәк: кардинал хәзрәтләренең гвардиячеләре очраган бер җирдә аларга бәйләнәләр, шуннан инде ул мескен егетләр, үз полкларының абруен төшермәс өчен генә булса да, үз-үзләрен якларга мәҗбүрләр.

— Карагыз әле, де Тревиль әфәнде! — диде король.— Карагыз әле! Монда сүз ниндидер монахлар общинасы турында икән дип уйларлык. Чыннан да, капитан-кадерлем, миндә сезне капитан дәрәҗәсеннән мәхрүм итеп, аны мадмуазель де Шемрога бирү теләге туа башлады — мин ул мадмуазельне монастырь назирәсе итәргә вәгъдә биргән идем. Тик сез мине коры

сүзегезгә ышана бу, дип уйламагыз. Де Тревиль әфәнде, Гадел Людовик дип атыйлар бит мине, менә хәзер күрербез...

— Нәкъ әнә шул гаделлегегезгә таянганга күрә дә сез галиҗәнапның карарын мин тып-тыныч һәм сабыр гына көтеп торачакмын.

— Бераз сабыр итегез, сабыр итегез. Озак көттермәм мин сезне,— диде король.

Бу вакытта инде уенда корольнең кул китә башлаган: ул оттырып ята иде, шуңа күрә — сүзебез өчен гафу итсеннәр — галиҗәнап уеннан таю ягын чамалый иде. Берничә минуттан соң король урыныннан торды, үзе тулысынча диярлек откан акчаларны өстәлдән алып кесәсенә салды да:

— Ле Вьевиль, минем урынга утырыгыз. Минем де Тревиль әфәнде белән бик мөһим бер эш хакында сөйләшәсем бар. Әйе шул, монда минем акчам — сиксән луи иде — оттыручыларга зарар булмасын өчен шул чаклы ук акча салыгыз. Барыннан да бигрәк гаделлек кирәк! — диде.

Аннары де Тревильгә таба борылды. Аның белән икәү тәрәзәләрнең берсенә таба атлаганда сүзгә башлады:

— Шулай итеп, әфәндем, сез кардинал хәзрәтләренең гвардиячеләре сезнең мушкетерлар белән талаш чыгарганнар дип әйтәсез?

— Әйе, галиҗәнап, нәкъ шулай.

— Ничек булган соң ул хәл? Сөйләп бирегез әле. Сез инде беләсездер, капитан-кадерлем: судья иң элек ике якны да тыңларга тиеш бит.

— Ай аллам! Бик гадәти, бик гади булган ул. Минем иң яхшы өч солдатым — сез галиҗәнапларга аларның исеме мәгълүм, тугрылыклары өчен аларны берничә тапкыр мактаганыгыз да бар, ә алар, сүземә ышаныгыз, галиҗәнап, үз хезмәтләренә җаннары-тәннәре белән бирелгәннәр,— менә шул, минем өч солдатым — Атос, Портос һәм Арамис әфәнделәр — бер Гасконь егете белән шәһәрдә йөреп кайтырга җыеналар — бүген иртән мин ул егетне алар карамагына тапшырган идем. Ялгышмасам, алар Сен-Җерменга барырга җыеналар. Дешо монастыре янындагы яланда очрашырга сүз куешалар. Көтмәгәндә генә болар янына, Каюзак әфәндене, Бикараны һәм тагын ике гвардиячене ияртеп, де Җюссак әфәнде килеп чыга. Бу әфәнделәр анда шундый зур компания белән указларны боза торган берәр ният белән килгәннәр, күрәсең.

— Алай, алай, хәзер генә төшенә башладым. Алар шунда үзләре дуэльдә сугышырга җыенганнармы әллә? — диде король.

— Мин аларны гаепләмим, галиҗәнап, ләкин, галиҗәнап, үзегез уйлап карагыз: кораллы биш кеше кармелиткалар монастыре янындагы аулак урынга нинди максат белән барырга мөмкин соң?

— Сез хаклы, Тревиль, сез хаклы!

— Минем мушкетерларны күргәч, болар ниятләрен үзгәртәләр, үзара дошманлыклары онытылып, полклар арасындагы дошманлык баш калкыта. Корольгә, фәкать корольгә генә турылыклы булган мушкетерларның кардинал хәзрәтләренә турылыклы гвардиячеләрнең күптәнге дошманнары икәне сез галиҗәнапка мәгълүм бит?

— Әйе, Тревиль, мәгълүм,— диде король күңелсез генә.— Франциядә мондый ике лагерьга бүленешне күрү бик күңелсез хәл. Король дәүләтендә ике баш булуы күңелсез хәл. Әмма ул хәл бетәчәк. Димәк, сез, гвардиячеләр мушкетерлар белән талаш чыгарганнар, дисез инде?

— Ихтимал, хәл шулай килеп чыккандыр дим мин. Ләкин тәгаен шулай дип әйтә алмыйм. Моның өчен Людовик Унөченчене Гадел Людовик иткән зирәклек нясе булырга кирәк.

— Сез хаклы, Тревиль. Ләкин сезнең мушкетерлар үзләре генә булмаганнар бит. Алар янында малай дип әйтерлек бер егет тә булган.

— Дөрес, галиҗәнап, берсе яралы әле, шулай итеп, корольнең өч мушкетеры — арада берсе яралы — һәм тагын бер малай кардинал хәзрәтләренең иң атаклы биш гвардиячесенә бирешмичә каршы торганнар, хәтта дүртесен егып салганнар.

— Җиңү бит бу! Зур җиңү! — дип кычкырып әйтеп куйды король бөтен йөзе белән балкып.

— Әйе, әйе, галиҗәнап, Сэ янындагы шикелле үк зур җиңү бу.

— Дүрт кеше, шуларның берсе яралы, берсе бала дип әйтерлек дидегезме әле сез?

— Аны егет дип әйтерлек тә түгел әле. Шул бәрелеш вакытында ул үзен шундый шәп егет итеп күрсәткән — мин батырчылык итеп аны сезгә тәкъдим итәргә уйлыйм әле.

— Ни исемле ул?

— Д'Артаньян исемле, галиҗәнап. Минем бер күптәнге дустымның улы. Сез галиҗәнапның атасы белән бергә ирекле булып сугышка катнашкан кешенең малае.

— Шул егет бик яхшы сугышкан дисезме? Бу хәлне әйбәтләбрәк сөйләп бирегез әле, Тревиль, минем сугышлар, бәрелешләр турында сөйләгәнне яратуымны беләсез бит.

Шулай дигәч, король Людовик XIII, горур гына кыяфәт белән киерелә төшеп, мыегын бөтереп куйды.

— Галиҗәнап,— диде де Тревиль дәвам итеп,— әйткәнемчә, д'Артаньян әфәнде — малай дип әйтерлек бер үсмер егет кенә әле, мушкетер булмагач, ул гади бер кала кешесе кебек кенә киенгән. Кардинал хәзрәтләренең гвардиячеләре, аның бик яшь булуын һәм бигрәк тә полк кешесе булмавын күреп, һөҗүм итә башлаганчы, аңа ул төштән китәргә кушканнар...

— Күрәсезме, Тревиль, беренче булып алар һөҗүм иткән бит,— диде король, капитанны сүзеннән бүлдереп.

— Бик дөрес, галиҗәнап, анысына шик-шөбһә юк. Шулай

итеп, алар монда китәргә куйшалар, ә ул болай дип җавап кайтара: мин рухым-җаным белән мушкетермын, бөтен җаным-тәнем белән король хәзрәтләренә бирелгәнмен, шулай булгач, мин мушкетер әфәнделәр ягында калам, ди.

— Шәп егет икән! — диде король пышылдап кына.

— Чыннан да ул мушкетерлар янында кала. Әйтергә кирәк: сез, галиҗәнап, бер дигән солдатлы булдыгыз, чөнки де Жюссак әфәндегә кардинал хәзрәтләрен чыгырыннан чыгарырлык коточкыч ударны кылыч белән шул егет ясаган.

— Жюссакны ул яралаганмыни? — диде король исе китеп.— Шул малаймы? Булмас, булмас, Тревиль!

— Сез галиҗәнапка мин ничек сөйләсәм, хәл нәкъ шулай булган.

— Жюссак — бөтен Франциядә иң яхшы кылыч остасы бит!

— Булса соң, ул үзеннән дә көчлерәк дошманына туры килгән.

— Минем ул егетне күрәсем килә, Тревиль, минем аны күрәсем килә. Ул егеткә берәр ярдәм кирәк булса, без ул эш белән шөгыльләнербез.

— Сез, галиҗәнап, аны кайчан кабул итә алырсыз икән соң?

— Иртәгә төш вакытында, Тревиль.

— Үзен генә алып килергәме?

— Юк, дүртесен дә алып килегез. Мин аларның барысына берьюлы рәхмәт әйтергә телим. Тревиль, аннары тугрылык бүләккә дә лаек бит.

— Галиҗәнап, алайса төш вакытында без Луврда булырбыз.

— Кече подъездан керерсез, Тревиль, кече подъездан. Кардинал белми калса да ярый.

— Баш өсте, галиҗәнап.

— Аңлыйсызмы, Тревиль: указ — ни әйтсәң дә указ ул. Ни әйтсәң дә, дуэльдә сугышу тыелган бит инде.

— Әмма бу бәрелеш, галиҗәнап, гадәттәге дуэль кагыйдәләренә бөтенләй сыймый. Тәпәләшү бу, моның дәлиле шул — алар, кардинал гвардиячеләре, минем өч мушкетер белән д'Артаньян әфәндегә каршы бишәү булалар.

— Анысы дөрес, тик шулай да кече подъездан керегез, Тревиль,— диде король.

Тревиль көлемсерәп куйды. Остазына каршы баланың ачуын кузгатты бит ул һәм зур нәрсәгә иреште. Капитан ихтирам белән король каршында баш иде дә, рөхсәт сорап, чыгып китте.

Шул кичне үк өч мушкетерга үзләрен король кабул итәчәге әйтелде. Корольне күптән белгәнлектән, алар әллә ни дулкынланмадылар. Тик д'Артаньян гына, Гасконь кешеләренчә хыялга бирелеп, бу хәлгә киләчәктәге уңышларының бер билгесе итеп карады һәм төн буе алдагы тормышын искиткеч матур

итеп күз алдына китереп ятты. Иртәнге сәгать сигездә инде ул Атос янында иде.

Д'Артаньян килеп кергәндә, мушкетер киенеп бетеп, чыгарга әзерләнеп тора иде. Король әле аларны төш вакытында гына кабул итәсе булгач, Атос Портос һәм Арамис белән Люксембург конюшнялары янындагы мәйханәгә барып, шунда бераз туп уйнарга сөйләшкән иде. Ул д'Артаньянны да үзләре белән барырга чакырды. Егет, бу уенны белмәсә дә, барырга риза булды. Вакыт әле иртәнге тугызлар тирәсе генә, д'Артаньян уникегә кадәр вакытын кая куярга белми иде.

Портос белән Арамис сөйләшенгән җиргә инде килгәннәр, туп чөеп уйнап маташалар иде. Барлык физик күнекмәләрдә зур житезлеге белән аерылып торган Атос д'Артаньян белән икәү мәйданчыкның икенче ягына барып басты да тегеләргә көч сынашырга тәкъдим итте. Тик беренче талпынуында ук Атос, сул кулы белән уйнаса да, мондый хәрәкәтләр өчен ярасы әле төзәлеп житмәгәнлеген тойды. Шулай итеп, д'Артаньян үзе генә калды, мин бөтен кагыйдәсенә туры китереп уйный белмим әле, дип искәртеп куйгач, ике мушкетер, очколарны санамыйча, туп чөештән генә уйный башладылар. Каты итеп Портос сугып җибәргән бер туп д'Артаньянның битенә бәреләязып узып китте, һәм шунда егет, әгәр туп битемә тигән булса, ихтимал, аудиенция булмый да калган булыр иде дип уйлап куйды, чөнки дигәндә, аның король сараена барып керерлек кыяфәте калмаган булыр иде. Гасконь егете буларак хыял итүенчә, аның бөтен киләчәге шушы аудиенциягә бәйләнгән иде бит. Ул әдәпле генә итеп Портос белән Арамиска баш иде дә, сезнең белән көч сынаша алырлык хәлгә житкәч уйнармын әле, диде. Шуннан соң, бауның читенә чыгып, тамаша кылучылар арасына кереп басты.

Д'Артаньянның бәхетсезлегенә каршы, тамашачылар арасында кардинал хәзрәтләренең бер гвардиячесе дә бар иде. Кичә генә иптәшләренең җиңелүенә бик ачуы котырган бу гвардияче шулар өчен үч алырга үз-үзенә ант иткән иде. Шушы очрак аңа бик җайлы булып күренде.

— Бу егетнең туптан куркуы бер дә гаҗәп түгел. Мушкетерлар өйрәнчеге генә бугай әле ул,— диде әлеге гвардияче күршесенә карап.

Д'Артаньян, елан чаккан кебек, ялт кына борылып карады, әлеге ачу китергеч сүз әйткән гвардиячегә күзләрен терәде.

— Нәрсә бар? — диде гвардияче, мыскыллы бер кыяфәт белән мыегын бөтергәләп.— Теләсәгез никадәр карагыз сез миңа, дустым: әйтәсе сүземне әйттем инде мин.

— Әйткән сүзегезнең мәгънәсе бик аңлаешлы булганлыктан һәм бернинди аңлатма соралмаганлыктан, минем арттан иярүегезне үтенәм,— диде аңа д'Артаньян.

— Кайчан иярергә? — дип сорады гвардияче шул ук мыскыллы кыяфәте белән.

— Хәзер үк, рәхим итегез.

— Сез минем кем икәнемне беләсездер дип уйлыйм?

— Мин сезнең кем икәнлегегезне бөтенләй белмим дә, белергә теләмим дә.

— Юкка теләмисез! Шәт, минем исемемне белсәгез, ул кадәр ашыкмас идегез.

— Ничек соң исемегез?

— Бернажу, баш өсте.

— Алайса, Бернажу әфәнде, мин сезне ишек төбендә көтеп торам,— диде д'Артаньян тыныч кына.

— Барыгыз, әфәндем. Артыгыздан чыгармын.

— Артык каушамагыз, әфәндем, безнең икәү бергә чыкканны беркем сизмәсен. Без кыласы эш өчен артык шаһитлар кирәк түгел.

— Яхшы,— диде гвардияче риза булып, исемен әйтүнең әллә ни тәэсире булмавына гаҗәпләнә калды.

Чыннан да, Бернажуның исеме, д'Артаньяннан кала, бөтен кешегә билгеле исем иде. Чөнки бу исем, король һәм кардиналның указларына карамастан, көн саен булып тора торган орыш-сугышларның бөтенесенә диярлек катнашучы бер кешенең исеме иде.

Портос белән Арамис уенга шулкадәр бирелгәннәр, Атос аларның уйнаганын шундый дикъкать белән карап тора иде — егетнең чыгып киткәнен берсе дә сизмәде. Д'Артаньян, кардинал гвардиячесенә вәгъдә иткәнчә, ишек төбендә туктап, көтеп тора башлады. Берничә минуттан гвардияче дә чыкты. Д'Артаньян төш вакытына король янына барырга соңга калудан куркып, бик ашыга иде. Әйләнә-тирәгә күз салды — урамда беркем күренми иде.

— Валлаһи, исемегез Бернажу булса да, бәхетегез бар икән! — диде ул дошманына мөрәҗәгать итеп.— Сезгә мушкетер өйрәнчеге генә туры килде. Хәер, бер дә борчылмагыз: булдыра алганымның барысын эшләргә тырышырмын мин. Сакланыгыз!

— Минемчә,— диде гвардияче, д'Артаньян сугышырга чакыргач,— минемчә, урыны уңышлы сайланмаган. Сен-Жермен аббатлыгы артында яисә Пре-о-Клеркта булса, җайлырак булыр иде безгә.

— Хак сүз сөйлисез,— диде д'Артаньян.— Тик, кызганычка каршы, вакытым бик аз шул минем. Нәкъ сәгать уникедә күрешүгә барасым бар. Шуңа күрә сакланыгыз, әфәндем, сакланыгыз!

Бернажу мондый эшкә үзен ике тапкыр чакырттыра торган кеше түгел иде. Шул минутта ук ул кулында кылычын ялтыратып дошманы өстенә ташланды — егетнең яшь булуын күздә тотып, аны өркетергә исәпли иде.

Әмма д'Артаньян да алдагы көнне генә яхшы ук сабак алган иде. Җиңәчәген тоеп күңеле җилкенгән, дошманының рә-

хим-шәфкать сораячагын уйлап горурлык хис кылган хәлдә, ул бер адым да артка чикмәскә карар иткән иде.

Кылычлар чыңлап аркылы чарпылыштылар. Д'Артаньян нык, каты тора иде, шуңа күрә дошманы бер адым артка чигәргә мәҗбүр булды. Шул чагында Бернажуның кылычы читкәрәк авышуыннан файдаланып, д'Артаньян кылычын кире алды да, алга ташланып, кылыч очы белән дошманының кулбашына төртте. Д'Артаньян шундук кылычын өскә күтәреп, бер адым артка чикте. Шуннан соң Бернажу аңа, чүп кенә бу, дип кычкырды да гайрәт белән алга ташланып, д'Артаньян кылычының очына үзе килеп кадалды. Әмма егылмады, җиңелдем дип тә әйтмәде, де Ла Тремуль әфәнде йорты ягына таба (анда аның бер кардәше хезмәт итә иде) чигенә генә башлады, шуңа күрә д'Артаньян, дошманына ясаган соңгы яраның ни дәрәҗәдә булуын белмәстән, аны туктаусыз кысрыклый бирде. Ихтимал, ул инде аны кадап үтергән дә булыр иде — шул вакыт урамнан килгән тавыш туп уйнаган йортка ишетелде. Гвардияченең ике дусты аның д'Артаньян белән нәрсәдер сөйләшкәнен һәм аннары, кылычын тотып, аның артыннан чыгып киткәнен күреп калганнар иде — әнә шулар йорттан йөгереп чыктылар да җиңүче егеткә ташландылар. Ләкин шул минутта ук ишектән, үз нәүбәтләрендә, Атос, Портос һәм Арамис та күренделәр һәм дус егетләренә һөҗүм иткән ике гвардияче өстенә ташланып, аларны үзләренә таба йөз белән борылырга мәҗбүр иттеләр. Шул чагында Бернажу җиргә ауды. Дүрт кешегә каршы икәү генә сугышкан гвардиячеләр:

— Де Ла Тремуль кешеләре, ярдәмгә чыгыгыз! — дип аваз салдылар.

Бу авазга де Ла Тремуль йортындагылар бөтенесе йөгерешеп чыгып, дүрт мушкетерга ташландылар.

Үз нәүбәтләрендә мушкетерлар да оран салдылар:

— Мушкетерлар, ярдәмгә килегез! — дип кычкырдылар.

Бу авазга беркайчан да җавап бирми калмыйлар. Мушкетерларның кардинал хәзрәтләренең дошманы икәнлеген бөтен кеше белә, кардиналга дошман булганнары өчен аларны яраталар да иде. Шуңа күрә Кызыл Герцогка (Арамис аны шулай дип атаган иде) хезмәт итмәүче башка полк гвардиячеләре мондый бәрелеш вакытында король мушкетерларын яклыйлар иде. Нәкъ шул вакытны бу тирәдән Дезэссар әфәнде полкыннан өч гвардияче узып бара иде, икесе дүрт иптәшенә ярдәмгә ташланды, өченчесе:

— Мушкетерлар, ярдәмгә килегез, ярдәмгә килегез! — дип кычкыра-кычкыра де Тревиль йортына таба чапты.

Де Тревиль әфәнде йортының ишегалды көндәгечә аның полкының солдатлары белән тулган иде — әнә шулар үз иптәшләренә ярдәмгә йөгереп килделәр. Шуннан барысы бергә өерелешеп сугышырга керештеләр, шулай да өстенлек мушке-

терлар ягында булып чыкты. Кардинал гвардиячеләре белән де Ла Тремуль кешеләре үз йортлары эченә чигенеп, капкаларын көчкә ябып өлгерделәр! Яралы Бернажуны инде авыр хәлдә моңарчы йортка алып кереп киткәннәр иде.

Мушкетерларның һәм аларга ярдәмгә килүчеләрнең ярсуы тәмам чигенә җитте һәм, де Ла Тремуль кешеләренең король мушкетерларына һөҗүм итүләренә үч итеп, аның йортына ут төртергә кирәк түгел микән дигән мәсьәлә дә туа башлады. Кем авызыннандыр ычкынган бу сүзне дәртләнеп куәтләргә керештеләр, тик, бәхеткә каршы, шул вакыт сәгать унберне сукты. Д'Артаньян белән дуслары король янына аудиенциягә барасыларын исләренә төшерделәр һәм, мондый усал шуклыкны алар киткәч эшләүләреннән шикләнеп, бу кайнар башларны тынычландырырга тырыштылар. Шулай да капкага берничә таш очмый калмады. Ләкин капкалары бик таза иде. Шуның белән халык бераз суына төште. Аннан тыш, мушкетерлар, халык төркеменнән аерылып, де Тревиль йортына таба юл тоттылар. Мушкетерлар капитаны бу хәлне инде белгән, тегеләрне көтеп тора иде.

— Тизрәк Луврга киттек! — диде ул.— Бер минутны да әрәм итмичә Луврга киттек, кардинал кисәтеп өлгергәнче корольне күрергә тырышабыз. Без бу хәлне аңа кичәгенең дәвамы итеп сөйләп бирәбез дә шуннан икесе бер булып китәр ул.

Де Тревиль әфәнде, дүрт дустын ияртеп, Луврга ашыкты. Ләкин анда барып җиткәч, мушкетерлар капитанының гаҗәбенә каршы, корольне Сен-Жермен урманына болан ауларга китте, диделәр. Де Тревиль әфәнде ике тапкыр кабатлап әйттерде һәм кабатлаган саен аның кашы җыерыла барды.

— Король хәзрәтләре кичә үк ауга барырга ниятләгән идеме? — дип сорады ул.

— Юк, галиҗәнап,— диде камердинер.— Бүген иртән баш егерь аңа король хәзрәтләре өчен бер болан чолгап алуларын килеп әйтте. Король башта бармыйм дигән иде дә, аннары, андый ләззәттән баш тартырга көче җитмичә, китеп барды.

— Анда киткәнче король кардинал белән очраштымы? — дип сорады де Тревиль.

— Очрашкан булуы ихтимал,— диде камердинер.— Бүген иртән мин подъезд төбендә кардинал хәзрәтләренең җигүле каретасын күрдем. Мин, кая җыена ул? — дип сорагач, Сен-Жерменга, дип җавап бирделәр.

— Бездән өлгеррәк булып чыктылар,— диде де Тревиль.— Бүген кич корольне күрермен мин, әфәнделәр. Сезнең үзегезгә килгәндә исә, аның күзенә күренмәскә киңәш итәм.

Бик акыллы киңәш иде бу, аннан да бигрәк — корольне бик яхшы белгән кешенең киңәше иде бу, шуңа күрә дүрт дус аның белән бәхәскә керергә уйламадылар да. Де Тревиль әфәнде аларга өйләренә таралышып, үзеннән хәбәр булганны көтәргә кушты.

Де Тревиль өенә кайткач: «Ашыгырга кирәк иде, шикаятьне беренче булып бирергә иде»,— дип уйланды. Бер хезмәтчесе аша де Ла Тремуль әфәндегә хат җибәрде, хатында де Ла Тремуль әфәндедән кардиналга хезмәт итүче гвардиячене йортыннан куып мушкетерларга һөҗүм иткән өчен үз кешеләренә шелтә белдерүен үтенде. Үзенең өлкән атбагары тарафыннан искәртеп куелган де Ла Тремуль әфәнде (Бернажу әнә шул атбагарның туганы иде инде), де Тревиль әфәндегә дә, аның мушкетерларына да зарлану урынсыз, бәлки киресенчә, мин үзем зарланырга тиеш идем, чөнки мушкетерлар минем хезмәтчеләремә һөҗүм иттеләр, хәтта йортымны яндырырга җыендылар, дип җавап бирде. Бу ике вельможа арасындагы бәхәс бик озакка сузылуы һәм һәркайсы, билгеле, үз сүзен куәтләве ихтимал иде, шуңа күрә де Тревиль әфәнде бөтен мәсьәләне ачыкларга тиешле бер чара уйлап тапты. Де Ла Тремуль әфәнде янына ул үзе барып кайтырга булды.

Де Ла Тремуль әфәнденең йорты янына җиткәч, ул үзенең килгәнлеген хәбәр итәргә кушты.

Вельможалар әдәпле генә итеп бер-берсенә баш иделәр. Араларында дуслык бәйләнеше булмаса да, бер-берсен ихтирам итә иде алар. Икесе дә абруйлы, олы җанлы кешеләр иде. Де Ла Тремуль, протестант буларак, король сараена бик сирәк йөргәнлектән һәм шул сәбәпле, берничә партиядә тормаганлыктан, гадәттә аның кешеләргә карата алдан билгеләп куйган мөнәсәбәте юк иде. Шулай да бу юлы ул де Тревильне ихтирам белән каршы алса да, гадәттәгедән салкынрак кабул итте.

— Әфәндем, без икебез дә үзебезне рәнҗетелгән кешеләр дип саныйбыз, шуңа күрә, әлеге хәлнең бөтен ягын икәүләп ачыклау өчен, мин сезнең янга килдем,— дип сүз башлады мушкетерлар капитаны.

— Бик ризамын,— диде де Ла Тремуль,— тик алдан ук әйтеп куям: мин әлеге хәлне бик яхшы беләм, бөтен гаеп сезнең мушкетерларыгызда.

— Сез, әфәндем, бик акыллы һәм гадел кеше, шуңа күрә мин алып килгән тәкъдимнән баш тартмассыз дип уйлыйм.

— Рәхим итегез, әфәндем, мин тыңлыйм.

— Өлкән атбагарыгызның туганы Бернажу әфәнденең хәле ничек?

— Хәле бик начар аның, әфәндем. Беләгендәге ярасыннан тыш — анысы әллә ни куркыныч түгел — аңа тагын бер тапкыр кадап үпкәсенә тидергәннәр. Табип аның сәламәтләнүенә өметләнми дип әйтерлек.

— Яралы аңындамы соң?

— Әйе, аңында.

— Сөйләшерлек хәлдәме?

— Бик кыенлык белән генә сөйләшә.

— Алайса без, эфэндем, аның янына барыйк та ходай исеменнэн аны ырымлап — ихтимал, ул озакламый аллаһе тэгалэ каршына китеп тэ барыр — чын дөресен эйттерергэ тырышып карыйк. Үз эшендэ ул үзе хөкемдар булсын, эфэндем, мин ул эйткэннэрнең барысына да ышаначакмын.

Де Ла Тремуль эфэнде бераз уйланып торды да, моннан да акыллырак тэкъдим табуы кыен дип ахрысы, шундук риза булды.

Икесе дэ яралы гвардияче яткан бүлмэгэ төштелэр. Үзенең хэлен белергэ дип килгэн бу ике мөхтэрэм эфэндене күргэч, авыру урыныннан торып утырмакчы булды, лэкин шундук хэле китеп, һушсыз калып диярлек кире урынына ауды.

Де Ла Тремуль эфэнде аның янына килеп, авыруга кечкенэ бер шешэ белэн тоз иснэтте, яралы һушына килде. Шуннан соң инде де Тревиль эфэнде, үзен авыруга йогынты ясады дип гаеплэмэсеннэр өчен, де Ла Тремульгэ яралыдан хэлне үзегез сорашыгыз дип тэкъдим итте.

Эш нэкъ де Тревиль эфэнде уйлаганча килеп чыкты. Үлем белэн тартышып яткан Бернажу дөреслекне яшереп кала алмады, хэлне чын булганынча сөйлэп бирде.

Де Тревильгэ исэ шул гына кирэк иде дэ. Ул, Бернажуга тизрэк сэламэтлэнүен телэп, де Ла Тремуль белэн саубуллашты да өенэ кайтып китте һэм дүрт дусны үзенэ төшке ашка чакыртып шундук кеше җибэрде.

Де Тревиль эфэндегэ аш мэҗлесенэ кунакларның каймагы — барысы да кардиналның дошманнары җыелды. Шуңа күрэ, билгеле инде, мэҗлес дэвамында эңгэмэ дэ кардинал хэзрэтлэре гвардиячелэренең икелэтэ җиңелүе тирэсендэ эйлэнде. Д'Артаньян ике сугышның да каһарманы булганлыктан, бөтен мактау сүзе аның өстенэ яуды. Бу юлы Атос, Портос һэм Арамис яхшы иптэш буларак кына түгел, бэлки андый мактауны күп ишетеп туйганга да, мондый хэлгэ бик шат иделэр.

Сэгать алтылар тирэсендэ де Тревиль: «Луврга барырга вакыт»,— дип белдерде. Аудиенция сэгате узган булганлыктан, ул инде кечкенэ подъезддан керергэ рөхсэт сорап тормады, бэлки үзенең дүрт юлдашы белэн алгы бүлмэгэ кереп утырды. Король эле сунардан кайтып җитмэгэн иде.

Безнең дус егетлэребез ярты сэгать чамасы көтеп утыргач, бервакыт барлык ишеклэр ачылып китеп, король хэзрэтлэренең сунардан кайтып җитүе хакында хэбэр салдылар. Д'Артаньянның йөрэге леп-леп итеп тибэ башлады. Менэ-менэ хэзер аның килэчэк язмышы хэл ителэчэктер. Ул, тынын кысып, король килеп керэсе ишеккэ таба күзен текэде.

Менэ бусагада Людовик XIII күренде. Юлдашларыннан иң алда килеп керде ул. Корольнең өстендэ тузанга батып беткэн сунарчы киеме, аягында — ботфорт, кулында камчы иде. Д'Артаньян аны күрү белэн үк зилзилэ булмый калмаячагын төшенде.

Корольнең кәефе бик начар икәнлеге күренеп торса да, сарай хезмәтчеләре ул узасы юл буена тезелешеп бастылар: король сараенда бөтенләй аның күзенә күренми калганчы ачулы карашына булса да эләгүне хуп күрәләр иде. Шул сәбәпле өч мушкетер өчесе дә, ике уйламыйча, бер адым алга атладылар, д'Артаньян исә, киресенчә, аларга ышыклана төшәргә тырышты. Атос, Портос һәм Арамисны король күреп белсә дә, яннарыннан узганда аларга хәтта күз дә салмады, аларны бөтенләй белмәгән шикелле, сүз дә кушмады. Де Тревильгә килгәндә исә, ул, корольнең карашы үзенә тукталгач, шундый бер ныклык белән керфеген дә какмый карап торды — король хәтта ихтыярсыздан карашын читкә алырга мәҗбүр булды. Шуннан соң инде король хәзрәтләре, нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә, үзенең аппартаментларына таба китеп барды.

— Эшләр шәптән түгел. Безгә бүген орден тәтемәс,— диде Атос елмаеп.

— Шушында бер ун минут көтеп торыгыз. Шул вакытка кире чыкмасам, минем өйгә кайтып китегез. Шуннан да артык көтүнең файдасы булмас,— диде де Тревиль.

Дүрт дус ун минут чамасы көтеп тордылар. Де Тревильнең кире чыкмавын күргәч, бик борчылып, кайтып киттеләр.

Ул арада де Тревиль әфәнде исә корольнең кабинетына бик кыю барып керде һәм аны кәефе бик начар бер хәлдә күрде. Король креслосында камчы сабы белән ботфортына суккалап утыра иде. Де Тревиль, бер дә аптырамыйча, уңайсызланмыйча, тыныч кына аның кәефен сорашты.

— Кәефем начар, әфәндем, бик начар. Эчем поша,— диде король.

Бу чыннан да Людовик XIII нең иң авыр чирләреннән берсе иде. Кайвакыт ул якыннарыннан берәрсен тәрәзә янына алып китә дә: «Эч поша, әфәндем! Әйдә бергәләп пошынабыз»,— дия торган иде.

— Ничек инде ул?! — дип гаҗәпләнгән кебек әйтеп куйды де Тревиль.— Галиҗәнапның эче поша? Соң сез, галиҗәнап, бүген сунардан ләззәт табып кайтмадыгызмыни?

— Әйе, ләззәт, әйтәсе дә юк! — дип мыгырданып куйды король.— Бөтенесе үчеп-бетеп бара, валлаһи. Белмим инде, киекләр эз калдырмыймы, әллә этләр ис тоймый башлаганмы. Без карт бер боланны кугынлыйбыз, шуны алты сәгать буе эзәрлекләп барабыз, инде тәмам хәлдән тайдырдык дип, Сен-Симон җыену белгертеп быргысын кычкыртырга гына торганда кинәт эт өере бер читкә каера да бер яшьлек болан артыннан ташлана. Менә күрерсез, миңа, лачын белән аулаудан баш тарткан кебек, кугыннан да баш тартырга туры килер. Эх, де Тревиль әфәнде, бик бәхетсез король булдым мин! Минем нибары бер карчыгам калган иде, өченче көн шул да җан тәслим кылды.

— Чыннан да, галиҗәнап, мин сезнең каты борчылуыгызны аңлыйм, зур бәхетсезлек булган. Шулай да сезнең лачын,

карчыга һәм башка шундый ау кошларыгыз шактый күп иде шикелле бит?

— Шуларны өйрәтерлек бер кеше юк. Лачын өйрәтүчеләр үлеп бетеп бара. Бер мин генә лачын белән аулау һөнәрен беләм. Миннән соң барысы да бетәчәк. Капкын, тозак, кыл бугалаклар белән генә аулаячаклар! Әгәр өйрәнчекләр хәзерләп калдырырга өлгерә алсам... Юк шул, кардинал эфәнде миңа бер минут та тынгылык бирми, һаман-һаман Испания турында тукып тора, Австрия, Англия турында! Әйе, кардинал дигәннән, де Тревиль эфәнде, мин сездән разый түгелмен.

Де Тревиль нәкъ шул сүзне көтеп кенә тора иде. Ул инде корольне күптән белә, аның мондый зарлануы, үзенә дәрт өстәп көч бирә торган дару шикелле, бер кереш сүз генә икәнен дә төшенә иде. Ул әйтергә җыенганын менә хәзер генә әйтә башлаячак.

— Сез галиҗәнап каршында мин бәхетсезегез нинди гаеп эшләде соң? — дип сорады де Тревиль бик гаҗәпкә калган бер төс белән.

— Үзегезнең вазифаларыгызны сез шулай башкарасызмы? — диде король, де Тревильнең соравына туры җавап бирмәскә тырышып.— Мин сезне ни өчен мушкетерлар капитаны итеп куйдым соң: сезнең кул астындагы солдатлар кеше үтереп йөрсеннәр, бөтен бер квартал халкын аякка бастырсыннар, бөтен Парижны яндыра язсыннар өченме? Һәм сез шул хакта ләм-мим сүз әйтмисез! Хәер, мин сезгә юкка чәпчимдер,— диде король.— Гаеп кылучылар тотып ябылгандыр инде, сез аларга тиешле җәзасы бирелгәнлеген генә әйтергә килгәнсездер миңа.

— Юк, галиҗәнап,— дип тыныч кына җавап бирде де Тревиль,— киресенчә, мин сезнең хөкем итүегезне сорап килдем.

— Кемне? — диде король гаҗәпләнебрәк.

— Яла ягучыларны,— диде де Тревиль.

— Менә монысы яңалык! — диде король.— Сезнең ул нәләт төшкере мушкетерларыгыз: теге Атос, Портос һәм Арамис, тагын теге Беарн егете, котырган шикелле, мескен Бернажуга ташланып, аны үтерә язганчы кыйнаганнар,— соңгы сулышын алып ятадыр инде ул, бичара,— сез шуны, бәлки, инкяр итәрсез? Шуннан соң алар герцог де Ла Тремуль йортын камап алып, ут төртергә җыенганнар,— сугыш көннәрендә алай эшләсәләр, анысы начар булмас иде әле, чөнки ул йорт — чын һугенотлар оясы, әмма тыныч вакытта мондый эш башкалар өчен бик яман үрнәк булыр иде. Шулай булгач, әйтегез әле: сез боларның барысын да инкяр итәргә җыенмыйсыздыр бит?

— Сез галиҗәнапка кем сөйләде икән бу әкиятне? — диде де Тревиль һаман да сабыр булырга тырышып.

— Кем сөйләсен, әфәндем! Мин йоклаганда кем уяу, мин күңел ачканда кем эшли, кем ил эчендәге һәм ил тышындагы — Франциядәге һәм Европадагы бөтен эшләрне идарә итә — шул әйтте.

— Галижәнап ходайны күздә тотып әйтә шикелле,— диде де Тревиль,— чөнки минем күз алдымда фәкать ходай гына сез галиҗәнаптан шулай өстен торырга мөмкин.

— Юк, әфәндем, мин дәүләтебезнең тертәге булган, минем бердәнбер хезмәтчем, бердәнбер дустым кардинал хәзрәтләрен күздә тотып әйтәм.

— Кардинал хәзрәтләре әле ул изге папа түгел.

— Сез ни димәкче буласыз, әфәндем?

— Бары тик папа гына ялгышмый, бу сыйфат кардиналларга хас түгел, димәкче булам.

— Ул алдый, миңа хыянәт итә, димәкче буласызмы? Димәк, сез аны гаеплисез? Алайса, аны гаеплим дип яшермичә туптуры әйтегез.

— Алай түгел, галиҗәнап. Ул үзе алданган, дим мин. Аңа ялган мәгълүматлар җиткергәннәр, дим. Сез галиҗәнап мушкетерларын гаепле итәргә ул ашыккан, ул аларга карата гадел түгел, мәгълүматларын яман чыганаклардан алган, дим.

— Гаепләү де Ла Тремуль әфәндедән, герцогның үзеннән башланган.

— Галиҗәнап, мин: герцог әлеге хәлне йөрәгенә бик якын ала, шуңа күрә аның гадел хөкем йөртүенә ышанып булмый, дип тә әйтә алыр идем, әмма алай дип әйтергә һич уйламыйм. Мин герцогны намуслы, яхшы бер кеше дип беләм һәм аның әйткән сүзенә ышанам, тик бер шарт белән...

— Нинди шарт белән?

— Сез галиҗәнап аны үз яныгызга чакырып сорашуыгызны, шаһитлардан башка, икәүдән-икәү генә калып, үзегез сорашуыгызны һәм герцог китү белән үк мине кабул итүегезне теләр идем.

— Алай икән! — дип куйды король.— Де Ла Тремуль әфәнде әйткәннәрнең барысын да сез дөрес дип кабул итәсезме инде?

— Әйе, галиҗәнап.

— Аның хөкеменә буйсынасызмы?

— Әйе.

— Ул таләп иткәннең барысын да эшләргә ризамы?

— Әйе, ризамын, галиҗәнап.

— Ла Шене! — дип кычкырды король.— Ла Шене!

Людовик XIII нең һәрвакыт ишек төбендә дежур торган ышанычлы камердинеры бүлмәгә килеп керде.

— Ла Шене,— диде король,— хәзер үк де Ла Тремуль әфәндене чакыра барсыннар. Миңа аның белән бүген үк кичен сөйләшергә кирәк.

— Де Ла Тремуль белән минем арада башка кешене кабул итмәскә галиҗәнап миңа сүз бирәме соң? — дип сорады де Тревиль.

— Беркемне дә кабул итмим,— диде король.

— Ул чагында сау булып торыгыз, галиҗәнап.

— Иртәгәгә кадәр, әфәндем.

— Иртәгә сәгать ничәдә килергә боерасыз, галиҗәнап?

— Ничәдә телисез — шунда.

— Тик мин бик иртә килеп, сез галиҗәнапны йокыгыздан уятмагаем дип куркам.

— Мине уятмагаегыз дип куркасызмы? Соң, йоклыйммыни мин? Минем хәзер йоклаганым юк, әфәндем. Черем иткәләп кенә алам мин — бөтен йокым шул. Иртән кайчан телисез — шунда килегез, теләсәгез җидедә үк. Әгәр мушкетерларыгыз гаепле булса — белеп торыгыз!

— Әгәр минем мушкетерларым гаепле булса, гаепле кешеләр сез галиҗәнап кулына тапшырылыр һәм сез аларга үзегез кирәк дип тапканча җәза бирерсез. Сез галиҗәнапның тагын башка теләкләре юкмы? Тыңлыйм. Мин әмерегезне үтәргә әзермен.

— Юк, әфәндем, юк. Гадел Людовик дип юкка гына атамыйлар мине. Сау булыгыз, әфәндем, сау булыгыз.

— Ходай ярдәменнән ташламасын сез галиҗәнапны!

Король начар йокласа, де Тревиль әфәнденең йокысы бу төнне тагы да начаррак булды. Ул кичтән кеше җибәреп, өч мушкетер белән аларның иптәшенә иртәнге җиденче яртыга минем янга килеп житсеннәр дип әйттерде. Аларны король сараена алып барганда берни вәгъдә итмәде, берни ышандырмады, үзенеке кебек алар язмышы да кыл өстендә торганлыгын әйтте.

Кечкенә подъездга кергәч, аларга көтеп торырга кушты. Корольнең аларга әле һаман да ачуы басылмаган булса, шыпырт кына китеп барырга кушты. Әгәр инде король аларны кабул итәргә булса, чакырырбыз, диде.

Де Тревиль корольнең шәхси кабул итү бүлмәсендә Ла Шенене күрде. Камердинер аңа, кичә кич герцог де Ла Тремульне өендә туры китереп булмады, ул өенә кайтканда сарайга килер өчен вакыт бик соң иде инде, герцог менә әле генә килде, хәзер король янында, диде.

Бу соңгы хәл де Тревиль әфәнденең күңеленә бик хуш килде. Хәзер инде ул де Ла Тремуль чыгып китеп король янына үзе кергән арада бернинди чит йогынты булмаячагына ышанып тора ала иде.

Чыннан да, бер ун минут та узмагандыр, ишек ачылып китеп, кабинеттан де Ла Тремуль әфәнде килеп чыкты. Герцог, де Тревильне күреп, туп-туры аңа таба юнәлде.

— Де Тревиль әфәнде,— дип сүз башлады ул,— король хәзрәтләре мине йортым янында булган теге хәлне сорашырга дип чакырган иде. Мин аңа чын дөресен сөйләп бирдем, ягъни бу эштә минем кешеләр гаепле, дидем, шуның өчен сезнең алда гафу үтенергә әзер икәнлегемне әйттем. Инде үзем сезне очраткач, ул эшне миңа хәзер үк эшләргә рөхсәт итегез. Мине һәрвакыт үзегезнең дустыгыз дип санавыгызны үтенәм.

— Герцог әфәнде,— диде де Тревиль,— сезнең бик намуслы кеше булуыгызга ышанычым шундый нык иде — мин хәтта сездән башка король каршында үземне яклардай бүтән кешенең булуын теләмәдем дә. Ул өметем алданмаганлыгын күреп торам һәм сезгә Франциядә әле сезнең шикелле намуслы, яхшы ирләр калганы өчен рәхмәтемне белдерәм.

Кабинет ишегендә аларның сөйләшкәнен ишетеп торган король:

— Шәп! Бик шәп! — диде.— Тик сез әйтегез аңа, Тревиль: ул үзен сезнең дустыгыз дип атагач, минем дә аның бер дусты буласым килә, тик миңа илтифаты юк шул аның. Менә минем аны күрмәгәнемә өч ел була инде, кеше җибәреп чакыртып китергәч кенә күрдем үзен. Шуны сез аңа минем исемнән әйтегез, чөнки король үзе әйтә алмый торган сүз ул.

— Зур рәхмәт, галиҗәнап, зур рәхмәт. Тик мин сезгә, галиҗәнап, ихластан әйтер идем,— бу сүз де Тревиль әфәндегә кагылмый, әлбәттә,— король хәзрәтләре көненә әллә ничә тапкыр күрә торган кешеләр аңа тугрылыклырак дигән сүз түгел әле.

— Димәк, сез минем ни әйткәнемне ишеттегез, герцог? Бигрәк яхшы, бигрәк яхшы! — диде король, бер адым алгарак атлап.— Ә, бу сезмени, Тревиль? Сезнең мушкетерларыгыз кайда соң? Мин бит өченче көн үк инде аларны алып килергә кушкан идем. Нигә алып килмәдегез?

— Галиҗәнап, алар аста гына, сезнең рөхсәт белән Ла Шене аларны хәзер чакырып китерәчәк.

— Әйе, әйе, хәзер үк килсеннәр. Озакламый сәгать сигез була, ә тугызда мин башка кешеләрне көтәм... Китәргә мөмкин сезгә, герцог, сарайга килгәләп торыгыз... Керегез, Тревиль.

Герцог, баш иеп, ишеккә таба китте. Ул ишекне ачкан чакта баскычның өске идәнендә өч мушкетер белән д'Артаньян күренде. Аларны Ла Шене чакырып килә иде.

— Бирегәрәк килегез, бирегәрәк, батыр егетләр. Кая, бераз тиргим әле үзегезне,— диде король.

Мушкетерлар баш ия-ия корольгә якынлаштылар. Д'Артаньян алар артыннан атлады.

— Нәләт төшкере, ничек итеп сез дүртәү ике көн эчендә кардиналның жиде гвардиячесен сафтан чыгардыгыз соң? — дип дәвам итте Людовик XIII.— Күп бит бу, артык күп. Киләчәктә дә болай дәвам итсә, кардинал хәзрәтләренә өч атнадан ротасын өр-яңага алмаштырырга туры киләчәк. Ә мин указларны бөтен катгыйлыгы белән кулланырга мәҗбүр булачакмын. Бер кеше генә булса, анысы әле ярый, мин каршы килмим. Ә менә ике көн эчендә жиде кеше — кабатлап әйтәм: күп бит, артык күп бит бу.

— Шуна күрә дә, сез, галиҗәнап, үзегез дә күреп торасыз: алар бик уңайсызланалар, тәүбә итәргә ризалар һәм сездән гафу сорыйлар.

— Уңайсызланалар һәм тәүбә итәргә ризалар? Һе...— диде король шикләнгән бер төс белән.— Мин аларның хәйләкәр кыяфәтләренә ышанмыйм. Бигрәк тә әнә тегесенә, Гасконь кешеләренә охшаганына. Бирегәрәк килегез әле, әфәндем!

Д'Артаньян, король үзенә эндәшкәнен аңлап, мескен кыяфәтендә якынрак килде.

— Менә ничек! Сез бит миңа ниндидер бер егет турында сөйләгән идегез! Бала ич әле бу, бөтенләй сабый бала! Жюссакка коточкыч удар ясаучы шушы малаймы инде?

— Бернажуга да кылычы белән бик шәп ике удар ясаган.

— Чынлапмы?

— Аннан тагын әле шунысы да бар,— дип сүз кыстырды Атос,— әгәр мине Каюзактан ул коткарып калмаса, шушы минутта мин сез галиҗәнапларга иң тирән ихтирамымны белдерә алмаган булыр идем.

— Димәк, ул — чын демон, сезнең Беарн егете, нәләт яугыры, дияр иде минем мәрхүм атам! Мондый эштә бер генә камзул тузмас, бер генә кылыч сынмас. Ә Гасконь кешеләре әле һаман да ярлы бит, шулаймы?

— Хак сүз, галиҗәнап,— диде де Тревиль,— алар ягындагы тауларда алтын ятмалары табылганы юк әле, сезнең мәрхүм атагызга тәхет өчен көрәшендә зур ярдәм күрсәтүләре өчен ходай аларга бүләк итеп шундый бер могҗиза тудырса начар булмас иде югыйсә.

— Моннан инде нәтиҗә шул: мин атамның улы булгач, мине дә Гасконь кешеләре король иткән, шулаймы, Тревиль? Ярый, хәерле сәгатьтә булсын, миңа бик ошый бу... Ла Шене, барыгыз әле, минем кесәләрне актарып карагыз әле — кырык пистоль акча җыелмасмы анда, булса, монда миңа китерегез. Ә хәзер, егетем, ихлас күңелдән, яшермичә, булган хәлне сөйләп бирегез инде.

Д'Артаньян кичә булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде: король хәзрәтләрен күрәчәге шатлыгыннан йоклый алмыйча, аудиенциягә кадәр өч сәгать алдан дуслары янына баруын да, бергәләп мәйханәгә китүләрен дә, д'Артаньянның битемә туп тимәгәе дип куркуын күргәч, Бернажуның аны мыскыл итә башлавын һәм шуның өчен җан тәслим кыла язуын да, ә бирегә бернинди катнашы булмаган де Ла Тремуль әфәнденең йортсыз кала язуын да сөйләде.

— Шулай! Миңа герцог үзе сөйләгәнчә, нәкъ шулай!.. Бичара кардинал! Ике көн эчендә җиде кешесе, өстәвенә иң газиз кешеләре бит!.. Хәзер инде булды, җитте, әфәнделәр, ишеттегезме? Җитте! Сез инде Феру урамы өчен үч кайтардыгыз, хәтта артыгы белән кайтардыгыз. Сез канәгать булырга тиешсез.

— Сез галиҗәнап канәгать булсагыз, без дә канәгать,— диде де Тревиль.

— Әйе, мин канәгать,— диде король һәм, Ла Шене кулын-

нап бер уч алтын тәнкә алып, д'Артаньян учына салды.— Минә минем канәгать булуымның билгесе,— диде.

Ул заманда әле, безнең көннәрдәге шикелле, горурлык дигән нәрсә модада булмаган. Дворян кеше король кулыннан акча алганда үзен бер дә кимсетәләр дип санамаган. Шуңа күрә д'Артаньян да, һичбер унайсызланусыз, кырык пистоль алтын тәнкәне алып, бик әйбәтләп кесәсенә салып куйды, хәтта король хәзрәтләренә иелә-сыгыла рәхмәт тә укыды.

— Ярый, бик шәп,— диде король, стенадагы сәгатькә күз салып,— бик шәп. Хәзер инде сәгать тугызынчы ярты, сезгә китәргә рөхсәт. Тугызда кайбер кешеләрне көтәм дип әйткән идем бит сезгә. Турылыклы булуыгыз өчен сезгә рәхмәтемне белдерәм, әфәнделәр. Киләчәктә дә мин моңа ышана аламдыр бит, шулаймы?

— Галиҗәнап,— диде дүрт дус бердәвыздан,— королебез хакына без үзебезне тураклап ташлатырга да риза!

— Яхшы, яхшы! Тик тураклата гына күрмәгез. Минем өчен тураклатмасагыз яхшырак, файдалырак булыр...— Егетләр китә башлагач, король тавышын акрынайта төшеп: — Тревиль,— диде.— Сезнең полкта буш урын юк бит, аннан ары, без сынау үткәрмичә полкка алмаска дип карар да кылган идек, шулай булгач, бу егетне киявегез Дезэссарның гвардия полкына урнаштырып торыгыз... Ах, шайтан алгыры, кардинал хәзрәтләренең чырае нинди булачагын алдан ук күреп сөенеп торам! Чыгырыннан чыгачак бит ул, чыкса чыгар — анысы миңа барыбер. Мин гадел эш иттем.

Шуннан соң король, саубуллашкан кебек кулын күтәреп, де Тревильне чыгарып җибәрде. Капитан үзенең мушкетерлары янына китте. Ул килеп җиткәндә, тегеләр д'Артаньян алган кырык пистоль акчаны бүлешеп яталар иде.

Король әйткәнчә, кардинал чыннан да чыгырыннан чыкты һәм атна буе кичен шахмат уйнарга килмәде. Тик бу хәл корольгә кардинал белән очрашкан саен мөлаем гына елмаеп аны сәламләргә һәм бик ягымлы тавыш белән:

— Кардинал әфәнде, турылыклы сакчыларыгыз Бернажу белән Жюссак бичараларның хәлләре ничек? — дип сорарга бер дә комачауламый иде.

## VII

## *МУШКЕТЕРЛАРНЫҢ ӨЙЛӘРЕНДӘ ЧАКЛАРЫ*

Луврдан чыкканнан соң, д'Артаньян кырык пистоль акчадан үзенә тигән өлешне ничегрәк итеп тотканда әйбәтрәк булыр икән? — дип, дусларыннан сорагач, Атос аңа «Нарат күркәсе»ндә яхшы гына аш мәҗлесе ясарга, Портос хезмәтче ялларга, Арамис исә лаеклы бер сөяркә булдырырга киңәш итте.

Аш мәҗлесен алар шул көнне үк ясадылар, һәм табынга яңа хезмәтче аш китереп торды. Ашларны Атос сайлап китертте, ә лакейны Портос тәкъдим итте. Лакей дигәнебез Пикарди ягы кешесе иде, батыр мушкетер аны шул көнне әлеге аш мәҗлесе уңае белән яллаган иде; Ла-Турнель күпере өстендә очраткан иде аны Портос. Планше — яңа хезмәтченең исеме шулай иде — күпердән суга төкергәләп, су өстенә төкерек төшкәч боҗралар таралышканын карап тора иде. Портос, кешенең мондый шөгыль ярату тыныч күңелле булуын һәм төпле фикер йөртә белүен күрсәтә, диде дә, бүтән берни сорашып тормастан, Планшены ияртеп тә китте. Планше, бу кеше мине үзенә хезмәткә ала дип уйлап, аның дворяннарча эре кыяфәтле булуына бик сөенгән иде, әмма үзенә тиешле урында Мушкетон исемле, үзеише үк икенче бер кеше барлыгын белгәч, беркадәр кәефе китте. Портос аңа, йортымда иркенлекмуллык булса да, миңа бер хезмәтче бик җиткән, шуңа күрә д'Артаньянга ялланырга туры килер сиңа, дип аңлатты. Яңа хуҗасы оештырган аш мәҗлесендә хезмәт иткән чагында инде тегенең акча түләгәндә кесәсеннән бер үч алтын тәңкә чыгарганын күргәч, Планше, бәхетем бар икән, дип уйлады һәм, мондый байга туры килүенә бик сөенеп, ходаена рәхмәт укыды. Аш мәҗлесе тәмам булганчы ул күңелен шул ышаныч белән юатты, калган ашлар белән бик әйбәтләп тамак ялгады. Әмма кич җиткәч инде, хуҗасына урын җәйгән чагында, аның аллыгөлле хыяллары таралып юкка да чыкты. Алгы бүлмә белән йокы бүлмәсеннән торган квартирда нибарысы бер генә карават бар иде. Планше алгы бүлмәдә, д'Артаньян караватыннан алган одеялны җәеп, идәнгә ятты. Шуннан соң инде д'Артаньян өстенә одеял ябынмыйча гына йоклый торган булды.

Атосның да хезмәтчесе бар иде, ул аны үзенә яраштырып тәрбияләде. Аныкы Гримо исемле. Бу мөхтәрәм әфәнде,— без, әлбәттә, Атосны күздә тотып әйтәбез,— бик аз сүзле бер кеше иде. Менә бишме-алтымы ел инде ул Портос һәм Арамис белән бик якын дус булып яши. Шул вакыт эчендә Атосның дуслары аның елмайганын берничә тапкыр күрсәләр дә, көлгәнен бер тапкыр да ишетмәделәр. Сүзе аның бик кыска, тәэсирле, ул бары тик әйтергә теләгән фикерен генә әйтә, сүзенә берниндн бизәк-чачаклар өстәп маташмый. Нечкәлекләрен тәфсилләмичә, иң кирәклесен генә әйтә.

Атосның яше утыздан артмаса да һәм үзе әле тап-таза ир-егет булса да, аның сөйгән яры барлыгын берәү дә ишеткәне-сизгәне юк. Хатын-кыз турында ул беркайчан бер сүз катмый, бу темага сөйләшү аңа бер дә ошамаганлыгы сизелеп торса да,— андый чакта ул ара-тирә берәр әче сүз яки ямьсез искәрмә генә кыстыргалап куя,— үзе башкаларга хатын-кыз турында сөйләшергә комачауламый. Әнә шундый тыенкы, аз сүзле булуы, күп аралашмавы белән ул бик өлкән карт бер кеше кебек тоела иде. Шуңа күрә Атос, үз гадәтләрен үзгәртүне

кирәк санамыйча, Гримоны үзе кушканны бересүзсез үтәргә өйрәтте: хуҗасы ым кагуга яисә иренен кыймылдатуга ук эшкә керешә тегесе. Атос аның белән бик гайре табигый хәлләрдә генә сөйләшә иде.

Гримо, хуҗасын бик яратса да, аның акыллы булуына сокланса да, кайчакларны аңардан уттан курыккан кебек курка иде. Ул аның ни кушканын төшендем дип тиз-тиз генә эшкә керешә дә Атос теләгәннең нәкъ киресен эшләп куя. Шунда инде Атос җилкәсен генә сикертә дә, бернинди ачусыз-нисез, Гримоны тукмап-тәпәләп ташлый. Андый көннәрне ул беркадәр сүзчәнрәк тә булып китә иде.

Белгәнебезчә, Портос Атосның нәкъ киресе иде: ул күп сөйләшеп кенә калмый, өстәвенә каты кычкырып та сөйләшә. Хәер, анысын гаеп итеп тә булмый: Портосның сөйләгәнен тыңлыйлармы, юкмы,— аның өчен анысы барыбер. Ул үз сүзеннән үзе ләззәт табар өчен — рәхәтләнеп үз-үзен тыңлау өчен генә сөйли. Теләсә ни турында сөйләшә ала ул, тик фән-гыйлем өлкәсенә генә кагылмый, бала чагымда галим кешеләр минем тәмам гайрәтемне чигерделәр, дип сылтау тапкан була үзе. Кыяфәте, килеш-килбәте Атосныкы шикелле мәһабәт, солтанатлы түгел, баштарак таныш‌ып киткән чакларында Атосның аннан чибәррәк булуы Портосның ачуын да китергәли торган иде. Шуңа күрә ул аны, һич югы, затлы киеме белән уздырырга тырыша торган булды. Ләкин Атос гади мушкетер плащыннан, башын артка чөебрәк, бер адым алгарак чыгып бастымы — ул, купшы киенгән Портосны артка чигереп, яңадан үзенә тиешле урынны ала иде.

Портос, үзенә бер юаныч итеп, де Тревиль әфәнденең кабинеты алдындагы бүлмәдә һәм Луврдагы каравыл бинасында, бөтен кеше ишетсен дигәндәй кычкырып, үзенең хатын-кызлар белән чуалуы турында сөйли, Атос авызыннан исә беркайчан да андый сүз ишетмәссең. Иң соңгы вакытта Портос танылган судьяларның хатыннарыннан атаклы хәрбиләрнең хатыннарына, чиновник хатыннарыннан баронессаларга күчкән икән, үзенең ниндидер бер чит ил княгинясе белән мавыгуына да шактый аңлаешлы итеп ишарә ясады.

Иске бер мәкаль бар: хуҗасы нинди булса, ялчысы да шундый, диләр. Шуңа күрә хәзер инде Атос хезмәтчесеннән Портос хезмәтчесенә, Гримодан Мушкетонга күчик.

Мушкетон — Нормандия ягы кешесе, аның Бонифаций дигән юаш кына исемен хуҗасы Мушкетон дигән янгыравыклырак исемгә алмаштырган иде. Портоска хезмәтче булып яллапган чагында ул, мине бик һәйбәт ашатасыз һәм бик һәйбәт киендерәсез, дигән шарт куйды. Моннан тыш, үзенә һөнәрчелек белән шөгыльләнү өчен көн саен ике сәгать вакыт бирелүен сорады — монысы аның калган бүтән ихтыяҗлары өчен кирәк икән. Портос аның шартларына риза булды: мондый шартлар бик ошый иде аңа. Үзенең иске киемнәреннән һәм запас плащларыннан

ул Мушкетонга камзуллар тектерергә бирде. Портосның искемоскылары белән эш итүче бер тегүченең осталыгы аркасында (аның хатыны Портосны аристократ гадәтләреннән арындырырга тырыша иде) Мушкетон хуҗасы янында бик күркәм бер хезмәтче булып йөри башлады.

Арамиска килгәндә исә (без аның характерын инде ярыйсы ук яхшы тасвирлап үткән идек шикелле, хәер, аның үзенең һәм дусларының характерлары үсешен моннан соң да күздә тотарбыз),— аның хезмәтчесе Базен исемле иде.

Базенның хуҗасы кайчан да булса рухани булып китү өмете белән яшәгәнлектән, андый кешенең хезмәтчесе дә, рухани кешегә ярашлы рәвештә, һәрвакыт карадан киенеп йөри иде. Ул юаш, сабыр холыклы, юан гына гәүдәле, утыз биш-кырык яшьләрендәге Берри кешесе. Хуҗасы рөхсәт иткән буш вакытын дини китаплар укып уздыра, кирәк булганда бик шәп итеп аш-су да хәзерли белә, хәзерләгәне, берничә блюдодан гына торса да, бер дигән аш була. Башка мәсьәләләрдә исә ул берни күрми дә, ишетми дә, ничек итеп кенә сынасаң да, хуҗасына тугрылыгын бозып булмас иде.

Хәзер инде, хуҗалар белән дә, аларның хезмәтчеләре белән дә өстән-өстән генә дигәндәй бераз танышып киткәч, һәркайсының торак тирәсенә күчик.

Атос Люксембургтан ике-өч адымда гына Феру урамында тора. Бик пөхтә итеп җыештырган кечерәк ике бүлмәсе бар. Аңа шушы ике бүлмәне тапшырган хуҗабикә әле әллә ни карт түгел, үзе бик чибәр, тик өйдәшенә юкка гына бик ягымлы карап күз нурларын түгеп йөри иде. Әллә ни бай булмаган бу торакның кайбер төшләрендә элекке зиннәтле җиһаз әсәрләре дә күренгәли, мәсәлән: стенада бик бай итеп бизәлгән, һичшиксез, Франциск I заманыннан калган бер кылыч эленеп тора. Аның асыл ташлар белән бизәлгән сабы гына да ике йөз пистольдән ким тормыйдыр. Ләкин Атос иң кыен хәлгә төшкән чакларында да аны залог итеп салырга яисә сатарга риза булмады. Бу кылычка Портос та шактый вакыт кызыгып-ымсынып йөрде. Шуны кулга төшерү өчен гомеренең ун елын да кызганмас иде ул.

Бервакыт Портос, ниндидер бер герцогиня белән күрешергә йөргәндә, Атостан әлеге кылычны сорап тормакчы булды. Атос, бер сүз дәшмәстән, бөтен кесәләрен актарып, андагы кыйммәтле әйберләрен: акча янчыгын, прәшкә, алтын чылбырларын чыгарып салды да Портоска: «Мә, ал,— диде.— Кылыч ул стенага беркетеп куелган, хуҗасы бу йорттан киткәч кенә стенадан төшәчәк»,— диде. Кылычтан тыш, күз төшәрлек тагын бер нәрсә бар — анысы Һенрих III заманының гаҗәеп дәрәҗәдә нәфис киенгән, түшенә Изге Рух ордены таккан атаклы бер вельможасы портреты иде. Бу портретның Атоска да билгеле бер охшашлыгы бар, король орденнарына лаек булган әлеге

атаклы вельможа Атосның бабасы икәнлеген күрсәткән уртак гаилә чалымнары сизелеп тора иде.

Шуларга өстәп, иң соңгысы инде — камин кашагасында, бик нәфис эшләнүе белән башка нәрсәләрдән аерылып, кылыч белән портреттагы шикелле үк герб бизәге төшерелгән, оста ювелир кулы эшләгән искиткеч бер тартма тора. Бу тартманың ачкычын Атос үзе белән генә йөртә иде. Шулай да бервакыт ул аны Портос барында ачты, һәм Портос шунда бу тартмада бары тик хатлар һәм кәгазьләр генә сакланганын үз күзе белән күреп ышанды — анда мәхәббәт хатлары белән гаилә архивы саклана иде булса кирәк.

Портос Иске Күгәрчен оясы дигән урамда күрер күзгә бик бай сыман зур гына квартирда яши. Берәр дусты белән үзенең тәрәзәләре турысыннан узган саен ул (шул тәрәзәләрнең берсе каршында парадный укалы киемнән һәрвакыт Мушкетон басып торыр), башын күтәреп, кулы белән өскә таба ишарәли дә: «Менә минем хөҗрә шушы була инде»,— ди. Ләкин аның үзен беркайчан да өендә туры китереп булмый, беркайчан беркемне үзе белән бергә өскә менәргә чакырмый, һәм тыштан бик бай булып күренгән йортның эчендә чынлыкта нинди байлык барлыгын беркем белми иде.

Арамиска килгәндә, ул кунак бүлмәсе, аш бүлмәсе һәм йокы бүлмәсеннән торган кечкенә бер квартирда яши иде. Башка бүлмәләре кебек, йокы бүлмәсе дә беренче катта, тәрәзәсе берни күренмәслек куе булып үскән күләгәле, ямь-яшел кечкенә бер бакчага караган иде.

Д'Артаньянның ничек урнашканлыгы безгә мәгълүм инде, хезмәтчесе Планше белән дә танышып өлгердек.

Д'Артаньян, интрига тудырырга сәләтле күпчелек кешеләр шикелле, үзенең табигате белән бик кызыксынучан, бик төпченергә яратучан бер егет иде. Ул Атос, Портос һәм Арамисның чынлыкта нинди кешеләр икәнлеген бөтен көчен куеп белергә тырышып карады. Чөнки шушы кушаматлары астында алар үзләренең чын дворян исемнәрен яшереп саклыйлар; мәсәлән, шул ук Атосның чын вельможа икәнлеге бер чакрымнан күренеп тора. Ул, Атос белән Арамис турында белмәкче булып, Портостан сораштырып карады, Арамистан Портосның кем икәнлеген белмәкче булды.

Кызганычка каршы, Портос үзенең мыштым дусты хакында имеш-мимештән артыгын белми икән. Имештер, Атос мәхәббәте аркасында зур бер кайгыга тарган һәм кемнеңдер явыз бер хыянәте бу яхшы кешенең бөтен тормышын агулаган. Ләкин ничек, ни рәвешле булганлыгын беркем белми иде.

Портоска килгәндә, ике иптәшенеке кебек, бары тик де Тревиль әфәндегә генә мәгълүм булган чын исеменнән башка, аның тормышындагы бүтән якларны белүе әллә ни кыен түгел иде. Дан-шөһрәт сөючән һәм күп сөйләшүчән бер кеше булганлыктан, аны кристалл кебек үтәли күреп була иде. Тик

Портосның үз-үзен мактап сөйләгән сүзләренә ышанганда аның хакында ялгыш фикер тууы да ихтимал иде.

Аның каруы, Арамис, бернинди сере юк шикелле күренсә дә, үзе бер сер йомгагы кебек иде. Башкаларга кагылышлы сорауларга ул бер-ике сүз белән генә җавап кайтарса, үзенә кагылганнарын бөтенләй читләтеп узарга тырыша иде. Бервакыт д'Артаньян, озак кына сорашканнан соң, Арамистан дуслары Портосның ниндидер бер герцогиняны сөяркәсе иткән, имеш, дигән сүзне ишеткәч, гәптәшенең гыйшык мажараларына кагылышлы серләрен әйттерергә тырышып карады.

— Я, менә сез үзегез, сөекле дус, башкаларның баронесса, графиня, герцогинялар белән чуалуын бик матур итеп сөйлисез дә үзегез ничегрәк соң?..— дигән булды.

— Гафу итегез,— диде Арамис, аның сүзен бүлеп.— Мин бу нәрсәләрне Портос үзе сөйләгәнгә генә, минем алда бу гыйшык хәлләрен үзе кычкырып сөйләгәнгә генә сөйлим. Ләкин, ихластан әйтәм, кадерле д'Артаньян әфәнде, әгәр мин ул нәрсәләрне башка чыганаклардан белгән булсам яки үзе миңа сер итеп кенә сөйләгән булса, дөньяда миннән дә аз сүзле рухани булмас иде.

— Анысына мин шикләнмим,— диде д'Артаньян,— шулай да минем сезнең белән танышып китүемә сәбәп булган теге яулыктагы кайбер герблар сезгә дә яхшы ук таныштыр дип беләм.

Арамисның бу юлы ачуы килмәде, ул, бик тыйнак, сабыр кыяфәткә кереп, ягымлы гына итеп җавап кайтарды:

— Минем чиркәү әһеле булырга җыенганымны, шул сәбәпле гыйшык мажараларын ят итүемне онытмагыз, дустым. Сез күргән ул яулык миңа бүләк ителмәгән, бәлки бер дустым аны миндә онытып кына калдырган иде. Мин аларның — аның һәм ул сөйгән ханымның — абруен төшермәс өчен яулыкны яшерергә мәҗбүр булдым... Үземә килгәндә, минем сөяркәм юк һәм булдырырга теләмим дә. Бу мәсьәләдә мин зирәк Атостан үрнәк алам — аның да, минеке шикелле, мәгъшукасы юк.

— Соң, шайтан алгыры, сез бит аббат түгел, мушкетер лабаса!

— Вакытлыча гына мушкетер мин, дустым, кардинал әйтмешли,— теләгемнән тыш мушкетер. Әмма күңелем белән мин руханимын, ихластыр. Үзенә бер шөгыль булыр дип, бу эшкә мине Атос белән Портос тарттылар. Мин рухани булырга тиешле чакта гына минем өчен күңелсезрәк бер хәл килеп чыкты, ни белән... Хәер, анысы сезнең өчен кызык түгелдер, мин сезнең кадерле вакытыгызны гына әрәм итәм.

— Юк, юк, минем өчен бик кызык ул! — диде д'Артаньян, җанланып китеп.— Хәзер минем бер эшем дә юк.

— Шулаен шулайдыр да, минем хәзер догалар укыйсым бар шул,— диде Арамис,— аннары шигырьләр дә чыгарасым бар — д'Эгильон ханым шигырь сораган иде. Шуннан соң Сент-Оноре

урамына сугылып, де Шеврез ханымга иннек аласым бар. Менә күрәсез, дустым, сезнең ашыгыр җирегез булмаса, минем ашыгыч эшләрем бик күп.

Шулай дигәч, Арамис яшь дустына якты чырай белән кул бирде дә саубуллашып китеп барды.

Д'Артаньян өч яңа дусты турында белергә никхәтле тырышса да, барыбер шуннан артык берни белә алмады. Ул бүгенге көндә аларның үткәннәре турында сөйләгәннәргә ышанырга карар итте, киләчәктә үзен җентеклерәк һәм дөресрәк мәгълүматлар белән баетачакларына өмет баглап куйды. Хәзергә әле Атос аңа Ахилл булып, Портос — Аякс, ә Арамис Иосиф булып тоела иде.

Тулаем гына җыеп әйткәндә, егетләр бик күңелле яшиләр. Атос карта уйный. Тик гел оттырып кайта. Шулай да, дуслары өчен акча янчыгы һәрвакыт ачык булса да, алардан бурычка бер су да сорамый. Инде акчасы булмаганда сүз биреп уйнаса, ул икенче көнне иртән сәгать алтыда ук үзен бурычлы иткән кешене уяттырып, аңа тиешле суманы тапшырта иде.

Портос ара-тирә генә карта уйный. Андый көнне ул отып кайтса, кәефе дә бик шәп була, теле дә усаллана. Оттырып кайтса, берничә көнгә бөтенләй юкка чыга, яңадан күренгәндә инде аның йөзе агарып, ябыгып киткән була, ләкин кесәсендә аның акчасы да була.

Арамис беркайчан да андый уен уйнамый. Ул уңмаган бер мушкетер һәм табын янында иң күңелсез бер кунак. Кайчан гына карама — аның өендә һәрвакыт эше булыр. Кайчакларны табындагылар шәраб парыннан шактый җылынып, сүз кызып кына җиткәч, өстәл янында әле тагын ике-өч сәгать утырылыр дип чамалап торганда, Арамис, сәгатенә карап алып, урыныннан кузгала да, мөлаем гына елмаеп, табындагылар белән саубуллаша башлый, үзе әйтмешли, ул бер дин белгече белән очрашырга дип сүз куешкан, шуның белән күрешергә ашыга. Икенче бер вакытны исә аның, диссертация язасым бар дип, тизрәк өенә кайтасы була, дусларыннан үзен эштән аермауларын үтенә.

Андый вакытларда Атос матур йөзенә бик килешә торган сөйкемле елмаюы белән елмаеп кына куя, Портос исә, шәрабын эчә-эчә: «Валлаһи, бу Арамистан иң яхшы дигәндә дә чыкса бер авыл побы гына чыгар»,— дип сөйләнеп куя.

Д'Артаньянның хезмәтчесе Планше үз өлешенә тигән бәхетне егетләрчә кабул итеп алды. Көненә ул утыз су акча алып тора иде, ай буена өйгә сайрар кош шикелле хуш бер күңел белән кайтып керә торган булды, хуҗасына карата ягымлы һәм бик ихтирамлы иде. Каберчеләр урамындагы квартир өстендә кара болытлар куера башлагач, ягъни король Людовик XIII биргән теге кырык пистоль акча эреп бетә язгач, Планше зарланырга-чәпчергә керешт‌е. Атос аның бу кыланышын гайрәт чигергеч дип, Портос — затсызлык дип, Арамис исә көлке дип

атады. Атос д'Артаньянга бу юньсез бәндә белән араны өзәргә киңәш итте; Портос, аны бер тотып ярырга кирәк, диде. Арамис исә, галиҗәнап кеше үзе турында мактаудан башка сүз ишетергә тиеш түгел, дип кенә куйды.

— Сезнең өчегезгә дә алай дип әйтүе җиңел,— диде д'Артаньян.— Сез, Атос, Гримо белән ләм-мим сүз сөйләшмисез, аны сөйләшүдән тыясыз, шулай булгач, аңардан беркайчан да әшәке сүз ишетмисез; сез, Портос, бик байларча яшәп, Мушкетоныгызга илаһи бер кеше булып күренәсез; инде сез, Арамис, һәрвакыт дини эшләр белән шөгыльләнгәч, хезмәтчегез Базенда, бик юаш һәм диндар кешедә, үзегезгә карата зур ихтирам уята беләсез. Ә менә мин, аяк астында терәге дә, байлыгы да булмаган, мушкетерлыкка да, хәтта гвардиягә дә алынмаган бер кеше, хезмәтчем Планше күңелендә ничек итеп ярату, курку я булмаса ихтирам тойгылары уятыйм соң?

— Бик мөһим мәсьәлә бу. Өй эчендә генә хәл ителә торган эчке мәсьәлә. Йортта хатын-кызны үзенә тиешле урынына куйган кебек, хезмәтчеләрне дә башта ук үз урыннарына утыртырга кирәк. Бу хакта бераз уйлагыз әле,— диделәр өч дус.

Д'Артаньян, бераз уйлангач, һич югы Планшены тотып бер ярырга булды һәм бу эшне, башка вакыттагы шикелле, бик тырышып, җиренә җиткереп башкарды. Тәмам үткәзерлек итеп ярганнан соң, ул үз рөхсәтеннән башка аңа йортны һәм эшне ташлап йөрүдән катгый тыйды.

— Белеп тор: киләчәгем алдамый мине,— диде аңа д'Артаньян соңыннан.— Менә, күрерсең, яхшы заманнар килер әле, әгәр син минем янда калсаң, язмышыңнан бик разый булырсың. Мин артык яхшы күңелле галиҗәнапмын шул — сиңа үзеңне үзең харап итәргә юл куя алмыйм, сораганыңча, риза булып сине җибәрә дә алмыйм.

Д'Артаньянның мондый ысул белән эш итүе аның дипломатлык сәләтенә мушкетерларның тирән ихтирамын уятты. Планше үзе дә моңа таң калды һәм китү хакында бүтән авыз ачмады.

Егетләр әкренләп уртак бер тормыш белән яши башладылар. Беренче тапкыр гына провинциядән килеп, үзе өчен бөтенләй яңа бер дөньяга кереп чумганлыктан, моңарчы бернинди асыл зат гадәте булмаган д'Артаньян иптәшләренең гадәтләрен үзләштерә башлады.

Кыш көне сәгать сигездә, җәй көне алтыда торып, Тревиль әфәнде янына пароль белешергә һәм нинди яңалыклар барлыгын чамаларга бара торган булдылар. Д'Артаньян, мушкетер булмаса да, хезмәтен җиренә җиткереп башкара иде. Ул гел каравылда була, чөнки каравыл хезмәтен үтәүче иптәшен һәрвакыт озата бара иде. Аны мушкетерлар казармасында да беләләр, үзен яхшы иптәш дип саныйлар. Егетне беренче күрүдә үк белеп алган һәм ихлас күңелдән ярата башлаган де Тревиль әфәнде д'Артаньянны әледән-әле король алдында да мактап сөйли иде.

Шулай ук өч мушкетер өчесе дә үзләренең яшь иптәшләрен бик яраталар. Бу дүрт кеше арасындагы дуслык тойгысы һәм кон саен бер-берен берничә тапкыр күрәсе килү теләге — я берәр төрле сугыш уңае белән, я эш буенча, я берәр төрле күңел ачу буенча — аларны көн буе бер-берсе артыннан йөртә иде. Люксембургтан алып Сен-Сюльпис мәйданына хәтле, я булмаса Иске Күгәрчен оясы урамыннан Люксембургка чаклы бер-берен эзләп йөргән бу дусларны һәрвакыт очратырга мөмкин иде.

Ул арада де Тревиль биргән вәгъдә дә әкренләп тормышка аша бара иде. Көннәрдән беркөнне король кавалер Дезэссарга д'Артаньянны үзенең гвардия ротасына кадет итеп алырга кушты. Д'Артаньян, авыр сулап, өстенә гвардияче мундирын киде: бу киемне мушкетер плащына алмаштыру өчен бер дә кызганмыйча ул гомеренең ун елын бирер иде. Тик де Тревиль әфәнде аңа мондый яхшылыкны ике ел сынау үткәннән соң гына эшләргә вәгъдә итте,— хәер, әгәр д'Артаньянга корольгә берәр хезмәт күрсәтү җае чыкса яки икенче бер юл белән үзен бик шәп күрсәтә алса, бу срокның кыскаруы да ихтимал икән. Шушы вәгъдәне алганнан соң, д'Артаньян кайтып китте һәм икенче көнне үк хезмәтен башкарырга кереште.

Хәзер инде д'Артаньян постта чагында Атос, Портос һәм Арамиска аның белән бергә каравылда йөрергә чират җитте. Шулай итеп, Дезэссар әфәнденең ротасы д'Артаньян алынган көнне үз сафына бер генә кеше түгел, бәлки дүрт кеше кабул итте.

## VIII

## КОРОЛЬ САРАЕНДАГЫ ИНТРИГА

Ул арада король Людовик XIII биргән теге кырык пистоль акча да, дөньяда һәр нәрсәнең башы-азагы булган кебек, бетеп китте. Шуннан соң инде безнең дүрт дус өчен авыр көннәр килеп җитте. Башта бөтен компанияне үз акчасына Атос ашатты. Аннары аны Портос алмаштырды һәм бер мәртәбә югалып торуы нәтиҗәсендә (дуслары аның андый гадәтенә күнеккәннәр иде инде) ул тагы ике атна чамасы үзләренең иң кирәкле ихтыяҗларын канәгатьләндерә алды. Ниһаять, Арамиска да чират җитте. Үзенең әйтүенә караганда, ул дини китаплар сатып берничә пистоль акча юнәтә алган иде.

Аннары инде, башка вакытлардагыча, де Тревиль әфәндедән ярдәм сорарга туры килде: ул аларга түләнәсе акча исәбеннән беркадәр аванс бирде. Тик шактый бурычка баткан өч мушкетер белән әлегә бурычсыз гвардияче егет бу акчага гына әллә ни озак яши алмадылар.

Ахыр чиктә, озакламый иң кирәкле ихтыяҗларына да акча җитмәячәген сизгәч, алар, көч-хәл белән тугыз-ун пистоль акча

җыеп, Портосны карта уйнарга җибәрделәр. Тик бу көнне Портосның бәхете булмады: ул бөтен акчасын оттырып кайтты, өстәвенә тагын, түлим дип сүз биреп, янә егерме биш пистоль оттырган иде.

Шуннан соң инде акча кыенлыгы чын мәгънәсендә мохтаҗлыкка әйләнде. Тәмам ачыккан мушкетерларның, хезмәтчеләрен ияртеп, дуслардан берәрсе ашка чакырып сыйламасмы дигән өмет белән, урамнар һәм кордегардияләр буйлап эзләнеп йөргәннәре күзгә чагылгалап китә башлады. Чөнки, Арамис әйтүенчә, аларга бай чакларында уңга да, сулга да аш мәҗлесе өләшеп йөрергә кирәк булган, ярлы көнгә калгач инде, сирәкмирәк кенә булса да шуның әҗерен кайтарырга мөмкин булган булыр иде.

Атосны шундый җиргә дүрт тапкыр кунакка чакырдылар һәм ул дүртесендә дә дусларын хезмәтчеләре белән бергә шунда ияртеп барды. Портосны мәҗлескә алты тапкыр чакырдылар һәм ул да дусларын бу хөрмәттән мәхрүм итмәде. Арамисны сигез тапкыр аш мәҗлесенә дәштеләр. Күргәнебезчә, бу кеше, сүзе аз булса да, эшен күп эшли иде.

Башкалада бер танышы да булмаган д'Артаньянга килгәндә исә, ул нибары бер тапкыр гына Гасконь ягыннан чыккан бер попта иртән шоколад белән сыйланды, аннары бер тапкыр гвардия корнетына кунакка чакырылды. Ул поп йортына да, корнетка да бөтен армиясен ияртеп килде — попның ике айлык шоколадын ашап бетерделәр, корнет исә искиткеч бер юмартлык күрсәтте. Шулай да, Планше әйтмешли, күпме генә ашасаң да, нибары бер генә тапкыр ашап каласың шул.

Атос, Портос һәм Арамис тапкан сый бәрабәренә д'Артаньян нибары бер ярым гына аш мәҗлесе юнәтүенә уңайсызлана калды, чөнки теге поп йортында сыйлануны ярты аштан да артыкка санап булмый иде. Ул, бөтен компанияне ай буе ашатып торуын үсмерләрчә беркатлылыгы белән онытып, үзен башкалар өчен артык кашык дип санады. Бу зирәк акыллы, батыр, тәвәккәл дүрт егетнең дуслыгы,— ярым исерек хәлдә тулганып йөрү, кылыч уены белән шөгыльләнү һәм тегене-моны кыланудан тыш,— башка нәрсәне дә максат итәргә тиеш иде дигән нәтиҗәгә килде.

Чыннан да, алар кебек дүрт кеше, бер-берсе өчен малларын да, җаннарын да кызганмаучы, бер-беренә һәрвакыт ярдәм итүче, бергәләп кабул иткән теләсә нинди карарны, беркайчан артка чикмичә, аерым-аерым яисә бергәләп башкарып чыгучы дүрт егет, аерым-аерым яисә бергәләп теләсә нинди дошманнарына курку салырлык дүрт йодрык,— котылгысыз рәвештә, ачыктаначык, я булмаса, яшерен-батырын, туры яисә әйләнеч юл белән, хәйлә яки көч белән,— ирешергә теләгәннәре никадәр ерак булса да яки никадәр нык сакланса да,— шуңа котылгысыз рәвештә юл ярып чыгарга тиеш иде. Тик д'Артаньян шушы уйның моңарчы дуслары башына килмәвенә генә гаҗәпләнә иде.

Ул әнә шул хакта, дүрт тапкырга арттырылган шушы гаҗәеп бер көчнең нинди юлдан китәргә тиешлеге турында баш ватты. Бу көч белән, Архимед рычагына таянган кебек, бөтен дөньяны әйләндереп салырга мөмкин бит,— анысына ул шикләнми иде. Әнә шулай уйланып утырган чагында кинәт бик әкрен генә ишек шакыганнары ишетелде. Д'Артаньян, Планшены уятып, ишекне ачарга кушты.

«Планшены уятып» дигән сүздән укучы «инде төн җиткән икән яисә таң атмаган икән әле» дип уйламасын. Алай түгел. Әле сәгать дүртне генә сукты. Моннан ике сәгать элек Планше хуҗасы янына килеп ашарга акча сорагач, д'Артаньян аңа «Йокысы туйганның тамагы да туя» дигән мәкаль белән генә җавап биргән һәм Планше тамак туйдырасы урында йокы туйдырырга яткан иде.

Планше бүлмәгә шәһәр кешесенә охшаган гади генә киемле берәүне ияртеп керде.

Планшеның, йокысын туйдыруы өстенә, боларның ни сөйләшәселәрен дә бик беләсе килгән иде дә, йомыш белән керүче кеше д'Артаньянга, минем икәүдән-икәү генә бик мөһим бер эш хакында сөйләшәсем бар иде, диде.

Д'Артаньян, Планшены бүлмәдән чыгарып җибәреп, әлеге кешегә утырырга кушты.

Башта икесе дә сүзсез калдылар. Хуҗа белән кунак, бер-берсенең нindиpәк кеше икәнлекләрен алдан ук чамаларга тырышкан сыман, карашып тордылар. Ниһаять, д'Артаньян кунакның йомышын тыңларга әзер икәнлеген белгертеп баш иде.

— Миңа д'Артаньян әфәнде хакында батыр йөрәкле бер егет дип сөйләгәннәр иде,— диде кунак.— Шундый шөһрәте булган егеткә бер серемне чишү теләге туды миндә.

— Сөйләгез, әфәндем, сөйләгез,— диде д'Артаньян, бу эшнең нindидер файдасы булырын сизенеп.

Кунак кеше тагын чак кына тынып торды да сүзгә керешТе:

— Минем хатыным королева янында кастелянша булып хезмәт итә, әфәндем. Бик чибәр, бик акыллы хатын үзе, мине аңа өч ел элек өйләндергәннәр иде. Бирнәсе әллә ни зур булмаса да, аның каруы королеваның өлкән камердинеры Ла Порт әфәнде — аның исем атасы — хатыныма химаячелек итә...

— Я, шуннан, әфәндем, шуннан? — диде д'Артаньян, аны ашыктырып.

— Шуннан... Шуннан — шул,— диде кунак,— кичә иртән эш бүлмәсеннән чыгып килгән чагында хатынымны урлаганнар.

— Кем урлаган соң аны?

— Әлбәттә, кем урлаганын мин тәгаен әйтә алмыйм, шулай да бер кешедән шикләнәм.

— Кемнән шикләнәсез?

— Хатынымны күптән эзәрлекли торган бер кеше ул.

— Шайтан гына алсын!

— Тик, әфәндем, шунысын да әйтә алам: мәхәббәттән бигрәк политиканың катнашы зур бу эштә.

— Мәхәббәттән бигрәк политика...— дип җөпләде д'Артаньян, уйга калып.— Сез үзегез нишләргә уйлыйсыз соң?

— Белмим инде, нишләргә уйлаганымны мин сезгә әйтә алырмын микән...

— Әфәндем, белегез: мин сездән берни дә сорамадым. Минем янга сез үзегез килеп кердегез. Үзегез: бер серемне чишәргә булдым, дидегез. Үзегез теләгәнчә хәл кылыгыз. Сез әле миңа берниндә сер чишмәдегез — чыгып китә дә аласыз.

— Юк, әфәндем, юк! Сез миңа бик намуслы егет булып күренәсез, сезгә ышанам мин. Минемчә, монда сәбәп хатынымның үз гыйшык маҗараларында түгел, бәлки аннан бик күп югарырак торган бер ханымныкында.

Д'Артаньян, кунагына король сарае тормышын яхшы белгән бер кеше булып күренергә тырышып:

— Алай! Де Буа-Траси ханымның гыйшык маҗаралары түгелме? — дип куйды.

— Югарырак, әфәндем, бик күп югарырак.

— Д'Эгильон ханыммы?

— Югарырак.

— Де Шеврез ханыммы әллә?

— Югарырак, бик күп югарырак.

— Алайса, нимени...

— Әйе, әфәндем, нәкъ шулай,— диде кунак, куркуыннан чак ишетелерлек тавыш белән.

— Кем белән?

— Кем белән булсын — герцог белән инде...

— Герцог белән?..

— Әйе, әфәндем,— дип тагын да әкренрәк итеп мыдырданды кунак.

— Сез боларның барысын каян беләсез соң?

— Аһ... Каян беләм, имеш!

— Әйе, каян беләсез? Я бөтенләй миңа ышанасыз, я... үзегез беләсез...

— Мин боларны хатынымнан ишетеп беләм, әфәндем, үз хатынымнан.

— Ә ул каян белә?

— Де Ла Порт әфәндедән ишетеп. Мин сезгә королеваның ышанычлысы де Ла Порт әфәнденең хатынымның исем атасы икәнлеген әйтмәдеммени? Менә шул, де Ла Порт әфәнде, бичара королевабыз янында аның берәр ышанычлы кешесе булсын дип, хатынымны шунда эшкә урнаштырган иде — ул бичараны бит король ташлаган, кардиал аны эзәрлекли, башкалар барысы аңа хыянәт итәләр.

— Алай икән, алай, мәсьәлә бераз ачыклана төште.

— Әфәндем, моннан дүрт көн элек хатыным минем янга

кайткан иде — анда эшләвенең бер шарты итеп хатыныма атнага ике тапкыр гына минем янга кайтып килергә рөхсәт иткәннәр иде. Әйткәнемчә, хатыным мине бик ярата, шуңа күрә, кайткач, миңа сер итеп кенә королеваның бик зур борчуы барлыгын әйтте.

— Чынлапмы?

— Әйе, чынлап. Хатынымның әйтүенә караганда, кардинал хәзрәтләре королеваны элеккедән дә битәррәк эзәрлекли, җәберли икән. Ул королеваны сарабанда * белән килеп чыккан хәл өчен гафу итми икән. Сарабанда белән килеп чыккан хәл сезгә мәгълүмдер бит?

Д'Артаньян, берни белмәсә дә, белгән күренергә тырышып:

— Мәгълүм булмаска! Аны мин дә белмәгәч! — дип куйды.

— Шулай итеп, хәзер инде нәфрәт кенә түгел, үч алу бу!

— Шулай укмыни?

— Королева уенча...

— Ни дип уйлый королева?

— Аның исеменнән герцог Бекингэмга хат җибәргәннәр дип уйлый.

— Королева исеменнәнме?

— Әйе, герцогны Парижга китертеп бирәр тозакка төшермәкче булалар икән.

— Ах, шайтан алгыры!.. Хатыныгыз, әфәндем, сезнең хатыныгызның бу эшкә нинди катнашы бар соң?

— Аның королевага бик тугрылыклы икәнлеге бөтен кешегә мәгълүм бит. Я аны королева яныннан алырга телиләр, я, куркытып, королеваның серләрен әйттермәкче булалар, я инде, акча белән кызыктырып, аны шымчы итәргә ниятлиләр.

— Ихтимал,— диде д'Артаньян.— Ә аны урлаган кеше сезгә мәгълүмме соң?

— Сезгә әйткән идем инде бугай: мин ул кешене беләм шикелле.

— Ни исемле?

— Исемен белмим. Миңа аның кардиналның бик яраткан кешесе, аңа эт шикелле тугрылыклы бер кеше икәнлеге генә мәгълүм.

— Сезнең аны берәр тапкыр күргәнегез булмадымы?

— Әйе, хатыным бер тапкыр миңа күрсәткән иде аны.

— Аны күргәч танырлык берәр төрле билгеләре юк идеме?

— Әлбәттә, бар! Эре генә кыяфәтле, кара чәчле, кара тутлы, үткен карашлы һәм ап-ак тешле бер галиҗәнап ул. Чигәсендә җөе дә бар.

— Чигәсендә җөе дә бар! — дип кычкырып куйды д'Артаньян.— Өстәвенә, ап-ак тешле, үткен карашлы, кара тутлы, кара чәчле, эре генә кыяфәтле. Шул ул, Мёнгта очраган ят кеше.

---

* Испан биюе.

— Мәңгта очраган ят кеше, дидегезме?

— Әйе, әйе! Тик бу эшкә катнашы юк аның. Ягъни, мин ялгыш әйттем: эшне бик гадиләштерә ул. Әгәр сезнең дошманыгыз шул ук вакытта минем дә дошманым булып чыкса, мин икебез өчен дә үч алачакмын — менә шул. Әмма ул кешене каян табарга соң миңа?

— Анысын мин белмим инде.

— Аның кайда яшәве хакында сездә бернинди дә мәгълүмат юкмы?

— Юк шул. Бер тапкыр хатынымны Луврга озата барган вакытта хатыным ишектән кергәндә шул кеше аннан килеп чыкты, хатыным аны миңа әнә шунда күрсәткән иде инде.

— Ах, ул иблисне! — дип мыгырданды д'Артаньян.— Болардан гына берни белеп булмый шул әле. Хатыныгызны урлаганнарын сезгә кем ишеттерде?

— Де Ла Порт әфәнде.

— Сезгә ул әлеге хәлнең ничек булганлыгын бераз сөйләмәдеме?

— Ул аны белми — күрмәгән.

— Башка чыганаклардан да белә алмадыгызмы?

— Бераз белдем. Мин ни алдым...

— Нәрсә алдыгыз?

— Белмим инде... Минем тарафтан бу, бәлки, бик зур саксызлык булыр...

— Сез тагын баягы хәлгә кайтасыз. Хәзер инде, сезгә әйтсәм әйтим, чигенергә соңрак.

— Чигенмим мин, нәләт төшсен лә! — дип кунак карганыптиргәнеп үз-үзенә көч кертергә тырышты.— Бонасье намусы белән ант итеп әйтәм...

— Сез Бонасье исемле буласызмы?

— Әйе, минем фамилиям ул.

— Димәк, сез: «Бонасье намусы белән ант итеп әйтәм...» дидегез. Сүзегездән бүлдерүем өчен гафу итегез. Мин сезнең исемегезне кайдадыр ишеткәнем бар шикелле.

— Бик мөмкин, әфәндем. Мин шушы йортның хуҗасы булам бит.

— Ах, шулаймыни! — диде д'Артаньян, күтәрелә төшеп, баш иде.— Сез бу йортның хуҗасымыни?

— Әйе, әфәндем, әйе. Сез инде минем йортта өч ай яшисез, мәшәкатьләрегез бик күп булганлыктан квартир хакын түләп барырга да онытасыз бугай. Мин инде сезне бер тапкыр да борчымагач, минем бу игътибарымны искә алырсыз дип уйладым...

— Әлбәттә, әлбәттә, Бонасье әфәнде! — диде д'Артаньян.— Ихластыр, мондый игътибарыгыз өчен сезгә чын күңелемнән рәхмәт укыйм. Әгәр сезгә берәр файдам тиярлек булса, сезгә ярдәм итүне...

— Мин сезгә ышанам, ышанам, әфәндем! Мин болай да сезгә әйтергә җыенып йөри идем, Бонасье намусы белән ант итеп әйтәм, мин сезгә бик ышанам.

— Алайса, сүзегездә дәвам итеп, азагына хәтле сөйләп бетерегез.

Кунак кеше кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарып д'Артаньянга сузды.

— Хат! — дип куйды егет.

— Бүген иртән алдым.

Д'Артаньян хатны алды да, кичке караңгы инә башлаганлыктан, тәрәзә янынарак китте. Кунак аның артыннан иярде.

«Хатыныгызны эзләмәгез. Кирәге беткәч, аны сезгә кайтарырлар. Эзләп табарга маташсагыз — харап булырсыз», — дигән сүзләрне укыды д'Артаньян.

— Менә монысы анлашыла, ичмасам, — диде д'Артаньян. — Үзенә күрә бер өркетү-янау гына бит бу.

— Шулай булса да, минем котымны ала. Мин бит, әфәндем, хәрби кеше түгелмен, Бастилиядән бик куркам.

— Һм... Анысы минем дә Бастилияне яратуым сезнеке чамасы гына. Әгәр дә сүз кылыч белән сугышу турында барса — эш башка булыр иде.

— Мин бит, әфәндем, бу эштә сезгә нәкъ шулай дип исәп тоттым.

— Шулаймы?

— Сезне һәрвакыт шундый шәп мушкетерлар арасында күргәнлектән һәм аларның де Тревиль әфәнде мушкетерлары икәнен, шулай булгач, кардинал хәзрәтләренең дошманы икәнен белгәч, мин сезне һәм дусларыгызны, бичара королевабызның яклаучылары булып, шул ук вакытта кардинал хәзрәтләренә берәр шомлык эшләргә бик риза булырсыз дип уйладым.

— Әлбәттә.

— Аннан ары, болай дип тә уйладым: сез инде миңа өч ай торган өчен квартир хакы да тиешле булгач, аннан соң шул хакта бер тапкыр да исегезгә төшергәнем булмагач...

— Әйе, әйе, сез ул дәлилегезне әйттегез инде, мин аны бик нигезле дип саныйм.

— Аннан тыш, минем йортта күпме гомер яшәсәгез дә, сезгә квартир хакы турында киләчәктә дә әйтмәскә исәпләп...

— Бик яхшы!

— Аннан тыш, әгәр сезнең, ихтималга каршы, акча ягыннан кыенлыгыгыз булса, сезгә илле пистоль чамасы акча тәкъдим итәргә дигән ниятем дә бар...

— Искиткеч яхшы! Димәк ки, сез бай кеше, Бонасье әфәнде?

— Дөресен әйткәндә, мин хәлле кеше. Мин, галантерея белән сату итеп, елына ике-өч мең экю китерә торган капитал җыйдым. Моннан тыш, атаклы диңгезче Жан Мокеның соңгы сәяхәтенә беркадәр сума керттем. Шулай булгач, үзегез

аңлыйсыздыр, әфәндем... Нәрсә ул? — дип кинәт кычкырып җибәрде Бонасье әфәнде.

— Кайда нәрсә? — дип сорады д'Артаньян.

— Әнә тегендә, әнә тегендә...

— Кайда?

— Урамда, сезнең тәрәзәләр каршында, подъездда! Плащка төренгән бер кеше бар!

— Шул үзе! — дип, д'Артаньян белән Бонасье, һәркайсы үз дошманын танып, беравыздан кычкырып җибәрделәр.

— Ә, бу юлы ул, бу юлы миннән качып котыла алмас! — диде д'Артаньян.

Һәм кылычын суырып алды да бүлмәдән чыгып чапты.

Баскычта ул үзе янына килүче Атос белән Портоска очрады. Тегеләр читкәрәк тайпылып юл бирүгә, д'Артаньян алар арасыннан ук кебек атылып узды.

— Кая чабасың? — дип кычкырып калдылар мушкетерлар.

Д'Артаньян:

— Мёңгта очраган ят кеше! — дип кычкырды да төшеп китеп күздән дә югалды.

Д'Артаньянның ят кеше белән очрашуы турында, шулай ук бик чибәр бер мөсафир хатын килеп чыгуы һәм шуңа әлеге ят кешенең бик мөһим бер хат ышанып тапшыруы турында дусларына берничә тапкыр сөйләгәне бар иде инде.

Атос, әтисенең хатын д'Артаньян ыгы-зыгы эчендә төшереп югалткан, дип саный иде. Аның уенча, дворян кеше,— ә д'Артаньянның тасвир итүе буенча ул әлеге ят кешене, һичшиксез, дворян дигән нәтиҗәгә килгән иде,— дворян кеше хат урлау шикелле түбәнлеккә төшмәс, янәсе.

Портос бу вакыйгага ике гашыйкның сүз куешып очрашуы итеп кенә карады, д'Артаньян үзенең кызгылт-сары аты белән аларның күрешеп сөйләшүенә комачаулык иткән, диде.

Арамис исә, бу вакыйганың эчендә ниндидер бер сер ята, андый нәрсәләрне белергә тырышмау хәерлерәк, диде.

Шуңа күрә алар, д'Артаньян авызыннан чыккан сүзне ишетү белән, кем хакында әйтелгәнен шундук аңлап алдылар. Д'Артаньян ят кешене куып тотса да яки күздән югалтса да, барыбер өенә әйләнеп кайтачак дип, баскычтан менә бирделәр.

Алар килеп кергәндә д'Артаньян бүлмәсендә беркем дә юк иде: йорт хуҗасы, үзенең өйдәше белән ят кеше арасында булачак ызгышның нәтиҗәләреннән шүрләп һәм д'Артаньянның Бонасье әфәнде үзе телгә алган характер сыйфатларына сылтау итеп, моннан чыгып таю хәерлерәк булыр дигән фикергә килгән иде.

## IX

## Д'АРТАНЬЯННЫҢ ХАРАКТЕРЫ АЧЫЛА БАРА

Атос белән Портос уйлаганча, д'Артаньян ярты сәгатьтән соң әйләнеп кайтты. Ят кешене ул бу юлы да кулыннан ычкындырды — әлеге бәндә сихерче кебек әллә кай арада гына юкка да чыкты. Д'Артаньян, кылычын кулына тотып, якын-тирәдәге бөтен урамнарны йөгереп йөреп чыкты, ләкин эзләгән кешесенә охшардай берәүне дә очратмады. Ахыр чиктә ул башта ук нәрсә эшләргә тиеш булганлыгын төшенде: ят кеше сөялеп торган ишекне барып шакыды. Тик юкка гына унар-егермешәр тапкыр ишеккә чүкеч белән тукылдатты — эчтән берәү дә җавап бирүче булмады. Шушы тавышны ишетеп ишек төпләренә чыккан яки тәрәзәдән башларын сузган күрше йорт кешеләре: «Бу йортның ишекләре бикле, монда алты айдан бирле инде бер кеше дә тормый»,— дип аңлаттылар.

Д'Артаньян урамнан урамга йөгергән һәм ишек каккан арада ике дусты янына Арамис та килеп кушылды, шулай итеп, д'Артаньян үзенең өенә кайтып кергәндә бөтен компания җыелып беткән иде.

Егет шабыр тиргә батып, ачудан чырае бозылып кайтып керүгә, тегеләр өчесе күтәрелеп карадылар да беравыздан:

— Я, ничек булды? — дип сорадылар.

— Ничек булсын! — диде д'Артаньян, эшләпәсен караватка ташлап.— Чын иблистер ул кеше... шәүлә кебек, өрәк кебек юкка чыкты!

— Сез өрәккә ышанасызмы? — дип сорады Атос Портостан.

— Мин фәкать үз күзем белән күргән нәрсәгә генә ышанам. Гомеремдә дә өрәк күргәнем юк, шулай булгач, аңа ышанмыйм,— диде Портос.

— Тәүратта андыйларга ышанырга дип әйтелгән,— диде Арамис,— Самуилның шәүләсе Саул янына килгән, бу — дин тәгълиматы, аның дөреслегенә шикләнергә ярамый дип беләм мин.

— Ничек кенә булмасын, кешеме ул, җенме, җисми нәрсәме яки шәүлә генәме, иллюзияме яки чынмы — барыбер ул бәндә минем әҗәлем өчен туган. Аның качуы аркасында мин кулга йөз пистоль, хәтта артыгы белән, акча төшерерлек бер эшне ычкындырдым.

— Ничек итеп? — диделәр Портос белән Арамис икесе бер авыздан.

Күп сөйләшергә яратмаучан Атос та кызыксынган бер төс белән д'Артаньянга карады.

— Планше,— диде д'Артаньян хезмәтчесенә. Бу вакытта Планше, аларның ни сөйләшкәнен бераз гына булса да ишетергә чамалап, ишектән башын сузып тыңлап тора иде.— Бу йортның хуҗасы Бонасье әфәнде янына төшеп әйтегез әле:

безгә алты шешә Божанси шәрабы җибәрсен. Мин аны иң яхшы шәраб дип саныйм.

— Менә монысы ярый! — дип куйды Портос.— Сез йорт хуҗасына теләгән кадәр бурычка керә аласыз, күрәсең.

— Әйе. Бүгенге көннән башлап шулай,— диде д'Артаньян.— Бер дә борчылмагыз: шәрабы начар булса, икенче төрлесен китертербез.

Арамис, үгет биргән бер тон белән:

— Чамалап эш ит, чамадан ашмасын,— диде.

— Мин гел әйтә киләм бит: д'Артаньян безнең дүртебез арасында иң акыллы егет,— диде Атос. Аның бу сүзенә каршы д'Артаньян баш иеп куйгач, Атос гадәтенчә тынып калды.

— Шулай да нәрсә булды соң? — дип сорады Портос.

— Әйе, әйе, безгә дә чишегез инде ул серне, дускай,— дип, бу сүзне Арамис та куәтләп җибәрде.— Әгәр дә бу вакыйгага хатын-кыз абруе катнашмаса: алай була калганда, сезгә ул серне эчегездә генә саклау хәерле.

— Бер дә борчылмагыз: мин сөйлисе нәрсәдән берәүнең дә абруена зыян килмәс,— диде д'Артаньян.

Шуннан соң ул дусларына йорт хуҗасы белән булган әңгәмәсен сөйләп бирде, бу мөхтәрәм кешенең хатынын урлаган бәндә мин «Хөр Тегермәнче» кунакханәсендә бәйләнешкән теге ят кеше булып чыкты, диде.

— Начар эш түгел бу,— дип куйды Атос, оста белгеч шикелле, шәрабны эчеп карады да «шәп икән» дигән сыман баш какты.— Бу рәхимле кешедән бер илле-алтмыш пистоль каерып алырга була. Тик шул ягын да уйларга кирәк: алтмыш пистоль акча өчен дүрт кешенең җанын кыл өстенә кую мәслихәт микән?

— Онытмагыз: монда сүз хатын-кыз турында, урланган бер хатын турында бара. Аны, әлбәттә, куркыталар, ихтимал, газаплыйлардыр да — үзенең хакимәсенә тугрылыклы булганы өчен генә ул әнә шул язмышка дучар! — диде д'Артаньян, кыза төшеп.

— Әкренрәк сөйләш, д'Артаньян, әкренрәк! — диде Арамис.— Сез, минемчә, Бонасье ханымның язмышын йөрәгегезгә артык якын аласыз. Хатын-кыз ул безнең әҗәлебез өчен яратылган, безгә бөтен бәла-казаны шулар тудыра.

Арамис шулай дигәч, Атос иренен тешләп, кашын җыерып куйды.

— Мин Бонасье ханым өчен түгел, королева өчен борчылам,— диде д'Артаньян.— Король аны ташлаган, кардинал эзәрлекли, королева үз тарафдарларының бер-бер артлы башлары тәгәрәгәнен күреп тора!

— Нигә ул без иң дошман күргән кешеләрне — испаннар белән инглизләрне ярата икән соң?

— Испания — аның ватаны,— диде д'Артаньян,— шуңа күрә аның испаннарны, туган җиренең балаларын яратуы бик таби-

гый. Сезнең икенче шелтәгезгә килгәндә исә, ишетүемчә, ул барлык инглизләрне дә түгел, бәлки бер инглизне генә ярата.

— Дөресен әйтергә тиешмен: ул инглиз бик яратырлык-сөярлек кеше. Минем аның кебек затлы, чибәр кешене күргәнем юк әле, — диде Атос.

— Искиткеч киенә белүен әйткән дә юк инде, — диде Портос, бу сүзгә өстәп. — Ул энҗе сипкән чакта мин Луврда идем. Валлаһи дип әйтәм: шунда ике энҗе бөртеге табып алдым да соңыннан берсен-берсен унар пистольгә саттым. Ә син, Арамис, аны беләсеңме?

— Сезнең кебек үк мин дә бик әйбәт беләм, әфәнделәр. Мин аны Амьен бакчасында тотучыларның берсе булган кеше. Анда мине королеваның өлкән атбагары де Пютанж әфәнде керткән иде. Ул елларда мин семинариядә укый идем әле. Ул вакыйга, минемчә, королеваны мыскыллау булды.

— Шулай да герцог Бекингэмның кайда икәнлеген белсәм, мин аны королева янына җитәкләп алып барыр идем, һич югы кардиналга үч итеп, — диде д'Артаньян. — Безнең иң аяусыз дошманыбыз — шул кардинал бит. Әгәр дә без аңа берәр төрле этлек эшли ала торган булсак, мин хәтта җанымны кыл өстенә куярга да риза.

— Королева Бекингэмны ялган хат белән бирегә чакырып китертүләреннән курка, дип әйтмәдеме галантерейчы? — дип сорады Атос.

— Королева шулай дип курка икән шул.

— Туктагыз әле, — диде Арамис.

— Нәрсә бар? — диде Портос.

— Бернәрсә дә юк, дәвам итегез. Мин кайбер хәлләрне искә төшерергә генә тырышам.

— Мин хәзер дә әлеге хатынны урлаулары без әйткән хәлләргә бәйләнгән, хәтта, ихтимал, герцог Бекингэмның Парижга килүенә дә бәйләнеше бар, дигән фикердә торам, — диде д'Артаньян.

— Бу Гасконь егетенең акылы гаҗәп зирәк! — дип сокланып әйтеп куйды Портос.

— Мин дә аны тыңларга бик яратам. Аның сөйләшү рәвеше кызык, — диде Атос.

— Карагыз әле, галиҗәнаплар! — дип эндәште Арамис.

— Я, Арамисны тыңлап карыйк! — диделәр дуслар.

— Кичә мин аулак кварталда бер дин белгече янында булган идем. Гыйльми хезмәтләрем өчен кирәк булган чакта мин аның белән ара-тирә киңәшкәлим шулай...

Атос көлемсерәп куйды.

— Ул ерак бер кварталда яши, үзенең сәләтенә һәм эшенә ярашлы бер урында, — дип сүзендә дәвам итте Арамис. — Менә шул, мин алардан чыгып килгән чакта...

Шулай дигәч, Арамис сүзеннән бүленеп калды.

— Нәрсә булды? Сез алардан чыгып килгән чакта... шуннан?

Арамис, ялган сөйләгәндә котелмәгән бер кыенлыкка тертелгән кеше шикелле, кыенсынып калган кебек булды. Ләкин тегеләр бик кызыксынып, күзләрен текәп сүзнең дәвамын көтә башладылар, шулай булгач, аңа кире чигенергә чама калмаган иде инде.

— Шул дин белгеченең туганнан туган бер сеңелесе бар...— диде Арамис.

— Әһә! Сеңелесе бар! — дип куйды Портос, аны бүлдереп.

— Олы гына бер ханым,— дип ачыклый төште Арамис.

Өч дус көлешеп алдылар.

— Әгәр дә сез мин сөйләгәнгә ышанмыйсыз, көләсез икән, ул чагында миннән бүтән берни ишетмәссез,— диде Арамис.

— Без сезгә Мөхәммәт өммәтендәгеләр кебек ышанабыз, катафалклар кебек тып-тын булабыз,— диде Атос.

-- Алайса, дәвам итәм,— дип, Арамис сүзенә кереште.— Аның шул сеңелесе ара-тирә абзасы янына килгәләп йөри. Кичә ул миңа әнә шунда туры килде, мин аны каретасына чаклы озатып куярга тиеш булдым...

— Әһә, алай икән! Димәк, аның, дин белгече сеңелесенең, каретасы бар? — дип, Портос тагын аны сүздән бүлдерде — Портосның телен тыеп тора алмавы аның төп бер кимчелеге иде.— Бик матур танышлык инде бу, дустым.

— Портос, минем бер тапкыр сезгә әйткәнем бар инде: сез тыйнаксызрак кеше, шул сыйфатыгыз хатын-кыз алдында да зыян итә сезгә,— диде Арамис.

— Әфәнделәр, әфәнделәр, бик җитди эш бит бу! — диде д'Артаньян, хәлнең асылын төшенеп алып.— Мөмкин булса, шаяртусыз гына тыңлыйк әле. Сүзегездә дәвам итегез, Арамис!

— Кинәт шунда озын буйлы бер кеше, кара чәчле, дворяннарча манерлы, сезнең теге ят адәмне хәтерләтә торган бер кеше, д'Артаньян...

— Бәлки, шул үзе булгандыр,— дип куйды д'Артаньян.

— ... үзеннән ун адым чамасы арттарак биш-алты кеше ияртеп, минем янга килде дә: «Герцог әфәнде»,— диде, аннары: «Сез дә, ханым»,— дип, минем беләккә тотынып торган дамага эндәште...

— Дин белгеченең сеңелесенәме?

— Җитәрегез инде, Портос! Килешегезгә түзәрлек түгел,— дип кычкырды Атос.

— «Рәхим итеп каретага кереп утырыгыз, карышып та, тавышланып та маташмагыз», ди бу кеше.

— Сезне ул Бекингэм дип белгән, алайса! — диде д'Артаньян.

— Үзем дә шулай дип уйлыйм шул,— диде Арамис.

— Ә ханымны? — дип сорады Портос.

— Аны королева дип белгән! — диде д'Артаньян.

— Нәкъ шулай,— диде Арамис.

— Валлаһи, җендер бу Гасконь егете! Бернәрсәне дә ычкындырмый,— дип сокланып әйтеп куйды Атос.

— Чыннан да бит, буе-сыны белән дә, йөреше-торышы белән дә Арамис чибәр герцогка бик охшаган,— диде Портос.— Шулай да, минемчә, мушкетер киеме...

— Минем өстә озын итәкле плащ иде,— диде Арамис.

— Июль аендамы?! — диде Портос.— Синең теге галимең сине танып калмагайлары дип курка идемени?

— Минемчә, шпионны аның фигурасы алдаса да, йөзе...

— Минем башта киң тирәле эшләпә иде,— дип җавап бирде Арамис.

— Йа алла, дин гыйлеме өйрәнер өчен нинди генә сакланыр чара күрмиләр! — дип куйды Портос.

— Әфәнделәр! Әфәнделәр! — диде д'Артаньян, аларны бүлдереп.— Юк-бар белән шаяртып вакыт әрәм итмик әле! Төрлебез төрле якка китик тә галантерейчының хатынын эзләргә керешик — аны тапсак, бөтен интриганың сере чишеләчәк бит.

— Шундый дәрәҗәсез бер хатын! Чынлап та шуны эзләргә кирәк дип уйлыйсызмы сез, д'Артаньян? — диде Портос, аскы иренен бүлтәйтеп.

— Королеваның ышанычлы камердинеры де Ла Порт — ул ханымның исем атасы. Мин сезгә аны әйтмәдеммени әле, әфәнделәр? Аннан ары, ихтимал, королева бу юлы үзенә терәк булырдай кешене түбән дәрәҗәдәгеләр арасыннан табарга исәп тоткандыр. Югарыдагы кешеләрнең башлары еракта ук күренә, ә кардиналның күзе бик үткен.

— Ярый алайса, галантерейчы белән сөйләшегез, тик яхшы бәһагә килешегез,— диде Портос.

— Анысы кирәк түгел,— диде д'Артаньян.— Минемчә, ул түләмәсә, башкалар әйбәт түләр.

Шул вакытны ашыга-ашыга баскычтан менгән аяк тавышы ишетелде, шалтырап ишек ачылып китте дә дуслар киңәшеп утырган бүлмәгә бичара галантерейчы атылып килеп керде.

— Әфәнделәр! — дип аваз салды ул.— Алла хакы өчен, коткарыгыз мине! Аста дүрт солдат тора, мине кулга алырга килгәннәр. Зинһар, коткарыгыз! Коткара күрегез!

Портос белән Арамис шундук урыннарыннан кузгалдылар.

— Торып торыгыз! — диде д'Артаньян, тегеләргә ала башлаган кылычларын кире салып куярга ымлады.— Биредә батырлык түгел, сак була белү кирәк.

— Без бит инде бу хәлгә юл куя алмыйбыз...— дип каршы әйтеп карады Портос.

— Д'Артаньянга үзенчә эшләргә ирек бирегез,— диде Атос.— Янә кабатлап әйтәм: ул бездән акыллырак. Мин, һич югы, аңа буйсынам. Үзең теләгәнчә эш ит, д'Артаньян.

Шул чакны алгы бүлмәнең ишегеннән дүрт солдат күренде. Ләкин, кылычлы дүрт мушкетерны күргәч, алар туктап калдылар.

— Керегез, әфәнделәр, керегез! — дип кычкырды аларга д'Артаньян.— Сез минем йортка кердегез, ә без барыбыз да король белән кардинал хәзрәтләренең турылыклы хезмәтчеләре.

— Алайса, галиҗәнаплар, сез безгә кушылган боерыкны үтәргә комачауламассыздыр? — диде берсе — отряд башлыгы булса кирәк.

— Киресенчә, әфәнделәр, кирәк булса, без сезгә ярдәм дә итә алабыз.

— Нәрсә сөйли ул? — дип мыдырданды Портос.

— Ахмак син, тик тор! — дип пышылдады аңа Атос.

— Сез бит миңа вәгъдә иткән идегез...— дип чак ишетелерлек тавыш белән мыдырданып куйды бичара галантерейчы.

— Без үзебез иректә калсак кына сезне коткара алачакбыз,— дип тиз-тиз генә пышылдап әйтте аңа д'Артаньян.— Әгәр без сезне яклап маташсак, сезнең белән бергә безне дә алып китәчәкләр.

— Шулай да, минемчә...

— Рәхим итегез, әфәнделәр, рәхим итегез,— диде д'Артаньян кычкырып.— Бу кешене якларга минем бернинди нигезем юк. Бүген минем аны гомеремдә беренче тапкыр күрүем, өстәвенә әле, нинди йомыш белән килгән диген... анысын сезгә үзе сөйләп бирер: миннән квартир хакы сорарга килгән! Дөрес әйтәмме, Бонасье әфәнде? Җавап бирегез.

— Саф дөреслек,— дип мыдырданды галантерейчы,— ләкин мушкетер әфәнде әйтмәде бит...

— Минем турыда да, дусларым турында да, бигрәк тә королева турында ләм-мим бер сүз әйтмисез, югыйсә безнең бөтенебезне харап итәсез! — дип пышылдады аңа д'Артаньян.— Ягез, әфәнделәр, ягез! Бу кешене алып китегез.

Шулай дигәч, д'Артаньян тәмам аптырап, югалып калган галантерейчыны стражниклар кулына таба этеп җибәрде.

— Томана кеше сез, дустым. Акча сорап киләсез... Миннән, мушкетер кешедән! Төрмәгә тыгыгыз үзен! Кабатлап әйтәм, әфәнделәр: төрмәгә озатыгыз үзен, мин квартир хакы түләрлек акча җыйганчы, үзен шунда бикләп тотыгыз.

Шымчылар, рәхмәт укый-укый, корбаннарын алып чыгып киттеләр. Алар инде баскычтан төшеп барганда д'Артаньян кинәт башлыкларының җилкәсенә шапылдатып сугып алды да:

— Бер-беребезнең исәнлеге өчен бераз тотып куймыйбызмы? — дип, ике бокалга Бонасье әфәндедән алган Божанси шәрабы сала башлады.

— Минем өчен бик зур хөрмәт инде бу. Бик рәхмәт сезгә,— дип сөйләнде стражниклар башлыгы.

— Шулай итеп, сезнең исәнлеккә, кем әфәнде... ни исемле әле сез?

— Буаренар.

— Буаренар әфәнде!

— Сезнең исәнлеккә, галиҗәнап! Сорарга рөхсәт итегез: сезнең исем шәрифегез ничек була инде?

— Д'Артаньян.

— Сезнең исәнлеккә, д'Артаньян әфәнде!

— Барыбыздан да бигрәк король исәнлеге белән кардинал исәнлегенә! — дип кычкырды д'Артаньян әсәрләнгән кебек.

Шәрабы юньле булмаса, сакчылар башлыгы д'Артаньянның ихлас әйтүенә шикләнгән дә булыр иде, әмма шәрабы бик яхшы иде, шулай булгач, ул ышанмый булдыра алмады.

Стражниклар башлыгы ярдәмчеләре артыннан чыгып китеп, дүрт дус үзләре генә торып калгач:

— Нинди кабахәтлек эшләдегез сез монда? Ничек оят түгел! — дип кызып китте Портос.— Дүрт мушкетер үзләреннән ярдәм сорап килгән бичара бер кешене кулга алырга юл куеп торалар. Дворян кеше шымчы белән бергә шәраб эчә!

— Портос,— диде аңа Арамис.— Атос сиңа ахмак дип әйтте бит инде, мин дә аның сүзенә кушылырга тиеш булам... Д'Артаньян, бөек кеше икәнсең син, син де Тревиль әфәнде урынына калгач, мин синең химая итүеңне сорап, миңа монастырь назире булырга ярдәм итүеңне үтенермен.

— Берни төшенмим! Сез д'Артаньянның бу эшен дөрес дип табасызмыни? — диде Портос.

— Ничек дөрес булмасын, шайтан алгыры! — диде Арамис.— Дөрес дип табу гына түгел, бу эше өчен хәтта котлыйм, тәбрик итәм мин аны.

— Хәзер инде, әфәнделәр,— дип сүзгә кереште д'Артаньян, үзенең ни өчен шулай эшләгәнлеген Портоска аңлатып бирүне кирәк санамыйча,— берең — һәммәбез өчен, һәммәбез — берең өчен — моннан ары безнең девиз шул булыр, әйеме?

Портос:

— Ләкин...— дип каршы төшә башлаган иде, Арамис белән Атос бер тавыштан:

— Кулыңны суз да ант ит! — диделәр.

Портос, алар каршында җиңелеп калса да, үзалдына нидер сөйләнә-сөйләнә, кулын алга таба сузды. Һәм д'Артаньян әйткән сүзне дүртесе беравыздан:

— Берең — һәммәбез өчен, һәммәбез — берең өчен! — дип кабатладылар.

— Бик яхшы. Хәзер инде һәркайсыбыз үз өенә кайтып китсен,— диде д'Артаньян, әйтерсең ул гомере буе шулай боерык биреп өйрәнгән кеше иде.— Ләкин бик сак булыгыз, чөнки шушы минуттан алып без кардиналга каршы көрәш башлыйбыз.

## X

## УНЖИДЕНЧЕ ГАСЫРДА ТЫЧКАН ТОЗАГЫ

Тычкан тозагы безнең заманда гына уйлап табылган нәрсә түгел. Полиция дигән нәрсәне җәмгыять уйлап чыгарганнан соң, полиция тычкан тозагын уйлап таба.

Укучыларыбыз әле Париж полициясенең үзенчәлекле теленә күнегеп җитмәгәнлеген һәм үзебезнең унбиш елдан артык язу дәверебездә бу нәрсәгә карата мондый тәгъбирне беренче тапкыр куллануыбызны искә алып, сүзнең ни турында икәнлеген төшендеребрәк китәргә тырышырбыз.

Нинди генә йорттан булмасын, җинаять шиге төшкән берәр кешене кулга алалар икән, моны сер итеп саклыйлар. Квартирның алгы бүлмәсендә дүрт-биш полицейскидан засада оештырып, килгән бер кешегә ишек ачалар, ул кергәч исә ишекне ябалар да аны кулга алалар. Шулай итеп, шушы йортка килеп йөрүче кешеләр ике-өч көн эчендә барысы кулга алынып бетә.

Тычкан тозагы дигәнебез менә шул була инде.

Бонасье әфәнде квартирында да әнә шундый тычкан тозагы оештырдылар һәм, килгән бер кешене кулга алып, кардинал хәзрәтләренең кешеләре аннан сорау ала башладылар. Икенче катта д'Артаньян яши торган бинага керү юлы аерым булганлыктан, аның кунаклары андый күңелсез хәлгә очрамадылар.

Хәер, аның янына өч дустыннан башка кеше килеп йөрми дә иде. Алар өчесе дә, һәркайсы үзе белгәнчә, урланган ханымны эзләргә керештеләр, тик хәзергә берни тапмадылар, бернинди эзгә төшә алмадылар. Атос хәтта, җөрьәт итеп, де Тревиль әфәндегә берничә сорау да биреп карады. Гадәттә бик аз сөйләшә торган батыр мушкетерның мондый эше, әлбәттә, капитанны шактый гаҗәпкә калдырды. Ләкин де Тревиль әфәнде аларның эше турында берни белми, аннан тыш, кардиналны, корольне һәм королеваны соңгы күрүендә кардиналның нииндидер мәшәкатьле бер борчуы бар, король дә нәрсәгәдер тынычлыгын җуйган кебек тоелган иде, королеваның исә кызарып беткән күзләре аның я төнлә бөтенләй йокламаганлыгын, я бик елаган булуын әйтеп тора иде. Соңгысына де Тревиль әллә ни шаккатмады — чөнки королева иргә чykканнан бирле еш кына төннәрен йокламый һәм күп елый иде.

Һәрхәлдә, де Тревиль әфәнде корольгә һәм бигрәк тә королевага тугры хезмәт итәргә кирәклеген Атосның исенә төшереп куйды һәм бу теләген дусларына да җиткерергә кушты.

Д'Артаньянга килгәндә исә, ул үзенең өеннән чыкмый ята башлады. Бүлмәсен күзәтү пунктына әйләндерде. Бу йортка килеп тычкан тозагына эләгүчеләрнең бөтенесен тәрәзәдән күреп торды ул. Аннары, паркетны сүтеп, сорау ала торган аскы бина белән аның арасында бер кат түшәм генә калгач, ул

шымчылар белән гаепләнүчеләр арасында сөйләшкән сүзләрнең бөтенесен ишетеп тора башлады. Сорау алуга керешкәнче, тозакка төшүчеләрне бик җентекләп тентиләр, сораулары исә һаман бер нәрсәгә кайтып кала иде:

— Бонасье ханым иренә яки икенче бер кешегә тапшырырга дип берәр нәрсә бирмәдеме сезгә?

— Бонасье әфәнде хатынына яки икенче бер кешегә тапшырырга дип берәр нәрсә бирмәдеме сезгә?

— Сезгә берәр төрле серләрен ышанып сөйләмәделәрме алар?

«Берәр нәрсә белсәләр, андый сорау бирмәс иде алар,— дип уйлады д'Артаньян.— Шундый сорау туа: чынында нәрсә белергә тырышалар алар? Мөгаен, Бекингэм Парижда түгелме, ул королева белән күрешмәгәнме яки күрешәсе түгелме — шуны белмәкчеләрдер».

Д'Артаньян әнә шул фаразында туктап калды, бу фикеренең дөреслеккә якын булу ихтималы юк түгел иде.

Ә хәзергә тычкан тозагы туктаусыз эшләп тора, д'Артаньянның да дикъкате кимеми.

Бичара Бонасье кулга алынганның икенче көнендә кич, Атос де Тревиль әфәнде янына киткәч һәм сәгать тугыз тулу белән Планше йокларга дип урын җәяргә җыена башлагач, кемдер урам ягыннан тышкы ишекне шакыды. Ишек шундук ачылды да ябылды: тагын берәү тычкан тозагына килеп эләкте.

Д'Артаньян идән сүтелгән төшкә йөгереп килде, йөзтүбән ятып, бөтен игътибары белән йотылып тыңларга кереште.

Озакламый чырылдаган, аннары ыңгырашкан тавыш ишетелде, бу тавышны томаларга маташалар иде, ахры, сорау алырга уйламыйлар да иде.

«Ах, шайтан! — диде д'Артаньян.— Хатын-кыз бугай бу: аны тентиләр, теге карыша... Көч кулланалар... кабихләр!..»

Астагы хәлгә кысылмас өчен д'Артаньянга бөтен көчен куеп тыелып калырга туры килде.

— Мин сезгә әйтеп торам бит, әфәнделәр: мин бу йорт хуҗасының хатыны, әйтеп торам бит: мин Бонасье ханым, мин королевага хезмәт итәм! — дип кычкыра бичара хатын.

— Бонасье ханым! — дип пышылдады д'Артаньян.— Бөтен кеше эзләгән ханымны табу бәхете әллә миңа тидеме?

— Нәкъ сезне көтә идек без! — дип җавап бирделәр хатынга.

Тавыш тоныклана төште. Дөберди-шалтырый башладылар. Хатын дүрт ир кешегә каршылык күрсәтә алган кадәр генә карыша иде.

Хатынның:

— Җибәрегез мине... җибәр...— дигән тавышы ишетелеп калды. Бу аның әйтә алган соңгы сүзе булды.

Д'Артаньян:

— Авызына чүпрәк тутыралар, хәзер алып китәләр! — дип кычкырып җибәрде дә пружинадан атылган кебек сикереп торды.— Кылычны бир!.. Үземдә икән... Планше!

— Ни боерасыз?

— Бар, йөгер, Атос, Портос һәм Арамисны алып кил. Өчесеннән берсен туры китерми калмассың, бәлки, өчесе дә өйләрендәдер. Коралларын алсыннар, тизрәк монда килеп җитсеннәр... Ә, әйе, искә төште: Атос де Тревиль әфәнде янында бит әле.

— Кая барасыз сез, кая барасыз, әфәндем?

— Мин тәрәзәдән аска төшәм! — дип кычкырды д'Артаньян.— Болай тизрәк. Ә син паркетны тезеп-төзәтеп куй, идәнне себер дә, ишектән чыгып, мин кушкан җиргә йөгер.

— Ай, әфәндем, әфәндем, җиргә бәрелеп үләсез бит! — дип кычкырды Планше.

— Тавышлайма, ишәк! — дип җикерде аңа д'Артаньян.

Һәм тәрәзә төбенә тотынды да икенче каттан җиргә сикереп төште. Бәхетенә каршы, икенче кат әллә ни биек түгел иде, егетнең бер җире дә бәрелеп авыртмады.

Төшү белән тышкы ишеккә килеп, әкрен генә ишекне шакыды, үзе:

— Хәзер мин дә тычкан тозагына эләгәм, бу тычканга кагылган мәчеләр кирәкләрен алачаклар! — дип пышылдады.

Өстәге чүкеч ишеккә бәрелеп тә өлгермәде, йорт эчендәге тавыш тынып калды. Аяк тавышы ишетелде, ишек ачылып китте, һәм д'Артаньян, кылычын чыгарып, Бонасье әфәнденең квартирына кереп китте. Ишеккә пружина куелган иде, күрәсең, егет артыннан ул үзе ябылып калды.

Шуннан соң бу каргышлы йортта яшәүче башка кешеләр дә, күрше йортлардан да җан ачысы белән кычкырган авазлар, дөп-дөп иткән аяк тавышлары, кылычлар чыңлаганын һәм өстәл-урындыклар дөбердәгәнен ишеттеләр. Бераздан соң тавышка борчылып, «нәрсә бар икән?» дип тәрәзәдән башларын сузучылар яңадан ишек ачылып киткәнен һәм кара киемле дүрт кешенең атлап түгел, бәлки, өркеп качкан козгын кәтүе шикелле, очып чыкканын күрделәр. Алардан соң идәндә һәм өстәл чатларында аларның канатларыннан йолкынган йоннары гына, ягъни таланган кием һәм плащ кисәкләре генә тузгып калды.

Әйтергә кирәк, д'Артаньянга аларны җиңүе әллә ни кыен булмады, чөнки шымчыларның берсендә генә корал бар иде, анысы да каршы торган булып кына маташты. Дөрес анысы, калганнары да егет өстенә урындык, утыргычлар, хәтта чүлмәкләр дә ыргытып аны түндерергә маташып карадылар. Әмма Гасконь егете кылыч очы белән берничә тапкыр эләктергәләп алгач, тегеләр шөр җибәрделәр. Нибары ун минутлап вакыт эчендә д'Артаньян, аларны пыр туздырып, сугыш мәйданында батыр булып калды.

Гел баш күтәрү һәм кораллы бәрелешләр булып торган

замандагы Париж кешеләренә хас салкын кан белән тәрәзәләрен ачкан күршеләр, кара киемле дүрт кешенең ишектән чыгып чапканын күргәч тә, тәрәзәләрен кире яптылар. Бу хәлнең әле азагы булмый калмаячагын сизенделәр алар.

Аннары вакыт та инде шактый соң иде, ул заманда да, хәзерге кебек, Люксембург сараена чиктәш кварталда йокларга иртә яталар иде.

Д'Артаньян, Бонасье ханым белән икәү генә калгач, аңа таба борылды. Бичара хатын һушсыз калып диярлек креслода ята иде. Д'Артаньян тиз-тиз генә аңа күз йөгертеп алды.

Егерме биш-егерме алты яшьләрендәге коңгырт чәчле, зәңгәр күзле, бераз чөелебрәк торган борынлы, энҗедәй ап-ак тешле искиткеч чибәр бер хатын иде бу. Мәрмәр сыман ак тәнендә ак ахактагы төсле беркадәр алсулык та бар. Аның югары җәмгыять дамасына хас сыйфатлары шушының белән бетә иде. Куллары ак булса да, тупасрак рәвешле. Аяклары да аның аксөяк нәселеннән түгеллеген әйтеп тора. Тик, д'Артаньянның бәхетенә каршы, андый гына вак-төяк кимчелекләргә егетнең әллә ни исе китми иде.

Бонасье ханымны карый торгач, әйткәнебезчә, аның аякларына игътибар иткәч, д'Артаньянның идәндә яткан батист яулыкка күзе төшеп, шуны кулына алды. Яулыкның бер почмагына герб сурәте төшерелгән иде. Д'Артаньян Арамис белән бугазлаша язарга сәбәп булган теге яулыкта да шундый герб күргән иде һәм шуннан бирле андый яулыкларга шикләнеп карый башлаган иде. Шуңа күрә ул, берни әйтмичә, яулыкны Бонасье ханымның кесәсенә салып куйды. Шул минутта яшь ханым һушына килде. Күзен ачты да куркынып як-ягына каранды: квартирда теге кешеләр юк, ул үзен коткаручы егет белән ялгызы гына калган иде. Ханым шундук елмаеп егеткә кулын сузды. Бонасье ханымның елмаюы искиткеч сөйкемле, матур иде.

— Һай, әфәндем, сез мине коткарып калдыгыз. Сезгә бик зур рәхмәт инде,— диде ул.

— Ханым,— диде бу сүзгә каршы д'Артаньян,— мин бит теләсә нинди дворян эшләрдәй бер эш кенә эшләдем. Шуңа күрә сез миңа бернинди рәхмәт әйтергә тиеш түгелсез.

— Ай, юк, юк, мин үземнең рәхмәтле була белүемне сезнең алда раслый алырмын дип өметләнәм. Ул кешеләргә минем ни кирәгем булды икән? Мин аларны башта караклар дип торам. Бонасье әфәнде нишләп үзе биредә юк соң?

— Ханым, ул кешеләр карактан күп өлеш хәтәррәк. Кардинал хәзрәтләренең кешеләре алар. Иregез Бонасье әфәндегә килгәндә, аның монда булмавының сәбәбе шул — кичә ирегезне кулга алып, Бастилиягә озаттылар.

— Минем ирем Бастилиядәме? — дип кычкыра язып әйтеп куйды Бонасье ханым.— Нинди гаебе булды икән аның? Гөнаһсыз бер бәндә бит ул!

Яшь хатынның әле һаман курку әсәре бетмәгән йөзендә елмаю сыман бер төс чагылып китте.

— Нинди гаебе булганмы аның, ханым? — диде д'Артаньян.—Миңа калса, аның бердәнбер җинаяте шул — бер үк вакытта бәхетенә дә, бәхетсезлегенә дә каршы, сезнең иргез ул.

— Алайса, сезгә мәгълүмдер, әфәндем...

— Миңа сезне урлаган булулары гына мәгълүм.

— Кем урлаган соң, кем? Сез шуны белмисезме? Һай, белсәгез, әйтегез миңа!

— Кырык-кырык биш яшьләрдәге кара чәчле, кара тутлы бер кеше, сул чигәсендә җөе дә бар...

— Әйе, әйе! Исеме ничек?

— Исеме?.. Менә анысын әйтә алмыйм.

— Мине урлаганнарын ирем белә идеме соң?

— Урлаучы кеше җибәргән хаттан белгән ул аны.

— Ә ни өчен урлаганнарын беләме икән ул? — дип сорады Бонасье ханым, уңайсызлана төшеп.

— Минемчә, бу эшкә политиканың катнашы бар дип уйлый иде бугай ул.

— Башта мин алай булуына шикләнгән идем, хәзер инде мин дә шулай дип уйлыйм. Алайса, ул, яхшы күңелле Бонасье әфәнде, минем үземнән аз гына да шикләнмәде?

— Һич! Ул сезнең акыллы хатын булуыгызны, үзен яратуыгызны горурланып әйтте.

Бу сөйкемле яшь хатынның алсу иреннәреннән тагын бер тапкыр чак сизелерлек елмаю сирпелеп узды.

— Ә сез ничек кача алдыгыз соң? — дип төпченде д'Артаньян.

— Мин ялгызым гына калган чактан файдаланып качтым. Үземне ни өчен урлаганлыкларын бүген иртән төшендем дә җәймәләргә асылынып тәрәзәдән төштем. Ирем өйдәдер дип монда йөгереп кайттым.

— Аның яклавына ышанып мы?

— Ю-ук! Һай, бичара, мескен ирем! Аның мине яклап кала алмавын беләм. Ул башка бер юл белән безгә ярдәм итә ала иде, шуңа күрә мин аны кисәтеп куймакчы идем.

— Ни турында?

— Юк инде, анысы минем үз серем түгел! Шуңа күрә аны сезгә чишә алмыйм.

— Алай дигәннән, гафу итегез, ханым,— диде д'Артаньян,— мин үзем гвардияче булсам да, сезгә, саграк булыгыз, дип әйтергә тиешмен: минемчә, сер ышанып сөйләр өчен урыны бу түгел. Мин куып чыгарган шымчылар өстәмә көч алып киләчәкләр. Алар килеп җиткәндә без монда булсак, харап булабыз. Дөрес анысы, мин өч дустыма әйтергә дип кеше җибәргән идем җибәрүен, ләкин алар өйдәме, юкмы — анысын кем белгән.

— Әйе, әйе, хак сүз сөйлисез! — дип куркуга төшеп әйтеп

куйды Бонасье ханым.— Әйдәгез, чыгып йөгерик моннан, тизрәк качыйк!

Шулай дип, ул д'Артаньянны култыклап алды да ишеккә таба әйдәде.

— Кая йөгерәбез соң? Кая качабыз? — диде д'Артаньян, аптырашта калып.

— Иң башта бу йорттан ераграк китик. Аннары карарбыз.

Артларыннан ишекне дә япмыйча, алар өйдән чыктылар да Каберчеләр урамы буйлап йөгерделәр, аннары Король Чокырына борылып, Сен-Сюльпис мәйданына җиткәч кенә туктадылар.

— Ә хәзер нишлибез соң инде? Мин сезне кая озатып куйыйм? — дип сорады д'Артаньян.

— Ихластыр, сезгә ни дип әйтергә дә белмим,— диде Бонасье ханым.— Мин ирем аркылы де Ла Порт әфәндене чакыртып, аңардан соңгы өч көн эчендә Луврда ниләр булганын, миңа анда барып күренү хәтәр түгелме дип белешмәкче идем.

— Де Ла Порт әфәндене мин дә барып чакыра алам ич,— диде д'Артаньян.

— Әлбәттә. Тик бер кыенлыгы бар шул: Бонасье әфәндене Луврда беләләр, аны анда кертәләр, ә менә сезне белмиләр, шуңа күрә сезгә ишек ачмаячаклар.

— Һи, ачтырабыз аны! — диде егет.— Луврның берәр ишеге төбендә сезгә турылыклы капка сакчысы бардыр бит? Парольне әйткәч, ул...

Бонасье ханым егеткә текәлеп карап торды.

— Әгәр мин ул парольне сезгә әйтсәм, сез аны шунда файдалану белән онытырсызмы соң? — дип пышылдады хатын.

— Валлаһи, дворян сүзе! — диде д'Артаньян бернинди шик калмаслык тон белән.

— Яхшы алайса. Мин сезгә ышанам, сез бик әйбәт егеткә охшыйсыз. Бәлки, сезнең киләчәгегез дә турылыклы булуыгызга бәйләнгәндер.

— Мин сездән бернинди вәгъдәләр сорамыйм, корольгә хезмәт итү һәм королеваның күңеленә ошау өчен мин көчемнән килгәннең барысын намус белән эшләргә тырышачакмын. Миңа сез үзегезнең дустыгыз итеп карагыз,— диде д'Артаньян.

— Мине аңарчы кая яшереп торырсыз икән соң?

— Де Ла Порт әфәнде сезне барып алырдай берәр кешегез юкмы?

— Юк, минем бу эшне берәүгә дә белгертәсем килми.

— Туктагыз әле,— диде егет.— Атос йорты моннан ерак түгел бит... Әйе, шулай шул.

— Кем ул Атос?

— Минем бер дустым.

— Әгәр ул өйдә булып, мине күрсә?

— Өйдә юк ул. Мин сезне квартирга кертеп җибәрәм дә, бикләп, ачкычны алып китәм.

— Әгәр ул кайтып килсә?

— Кайтмый. Һич югы, д'Артаньян монда бер хатын алып килде, хатын хәзер шунда дип әйтәчәкләр аңа.

— Ләкин бу эш минем абруемны төшерүе ихтимал бит, аңлыйсызмы шуны?

— Исегез китмәсен! Анда сезне беркем белми. Өстәвенә, без хәзер әдәп саклап торырлык хәлдә түгелбез.

— Яхшы, алайса. Әйдәгез, дустыгыз өенә киттек. Кайда тора ул?

— Феру урамында, моннан ике-өч кенә адымда.

— Әйдәгез.

Шуннан алар йөгереп китеп бардылар. Д'Артаньян уйлаганча, Атос өендә юк иде. Егет, ачкыч алып (Атосның дусты буларак, аңа ачкычны берсүзсез бирәләр иде), баскычтан менде дә Бонасье ханымны алда тасвирлап үтелгән кечкенә генә квартирга кертеп җибәрде.

— Үз өегездәге шикелле булыгыз,— диде егет.— Туктагыз әле: ишекне эчтән бикләп алыгыз да беркемгә дә ачмагыз, өч тапкыр шакысалар гына ачарсыз... менә болай,— дип, д'Артаньян өч тапкыр шакып күрсәтте — ике тапкыр шактый каты итеп бер-бер артлы сукты, өченче тапкырын әкренрәк, бераз көттеребрәк шакыды.

— Яхшы. Хәзер инде минә сезне өйрәтергә чират,— диде Бонасье ханым.

— Әйтегез — тыңлыйм.

— Луврга барып, Эшель урамына чыга торган ян капка катындагы ишекне шакыгыз. Жерменны сорагыз.

— Яхшы. Шуннан соң?

— Ул сездән сорар: «Ни кирәк?» — дияр, җавап урынына сез аңар Тур һәм Брюссель дип ике сүз әйтерсез. Шуннан ул сез кушканны эшләр.

— Мин аңа нәрсә кушам соң?

— Королеваның камердинеры де Ла Порт әфәндене чакыртасыз.

— Ул аны чакырып, де Ла Порт әфәнде чыккач?

— Аны минем янга җибәрәсез.

— Бик шәп. Әмма мин сезне тагын кайда һәм кайчан күрә алам соң?

— Ә сезнең мине яңадан бик күрәсегез киләме?

— Әлбәттә!

— Ул чагында бу хакта мин үзем кайгыртырмын, сез борчылмагыз.

— Сүзегезгә ышанам.

— Ышаныгыз.

Д'Артаньян Бонасье ханымга саубуллашып баш иде, аның кечкенә генә сөйкемле гәүдәсенә мәхәббәт тулы бер караш

ташлап алды, баскычтан төшеп барган чагында артта шапылдап ишек ябылганын һәм йозакта ике тапкыр ачкыч борылганын ишетте. Тиз генә йөгерә-чаба Луврга барып житте. Эшель урамы ягындагы ян капкага якынлашканда сәгать ун сукканны ишетте. Әле без тасвир иткән вакыйгалар нибары ярты сәгать эчендә булып узган иде.

Хәл нәкъ Бонасье ханым әйткәнчә булды. Парольне ишеткәч, Жермен баш иде. Ун минут та үтмәгәндер, Ла Порт әфәнде капка сакчысы бүлмәсенә килеп тә житте. Д'Артаньян бернике сүз белән генә хәлне сөйләп бирде һәм Бонасье ханымның кайда икәнлеген әйтте. Ла Порт адресны ике тапкыр кабатлады да ашыгып ишеккә китте. Ләкин ике-өч адым атлагач та, кире борылып килде.

— Егетем, сезгә бер киңәш бирергә рөхсәт итегез,— диде ул, д'Артаньянга мөрәҗәгать итеп.

— Нинди киңәш?

— Бу хәлләрдән сезнең өчен күңелсезлекләр килеп чыгуы мөмкин.

— Шулай дисезме?

— Әйе. Сәгате гел артка кала торган берәр дустыгыз юкмы сезнең?

— Я, шуннан нәрсә?

— Сез аның янына барыгыз, соңыннан ул сезне сәгать унынчы яртыда минем янда иде дип әйтерлек булсын. Юристлар моны алиби дип атыйлар.

Д'Артаньян моны бик акыллы киңәш дип тапты һәм бөтен көченә де Тревиль әфәнде янына йөгерде. Ләкин кунак бүлмәсенә кермичә (анда гадәттәгечә халык күп иде), кабинетка узарга рөхсәт сорады. Д'Артаньян монда бик еш булганлыктан, аның үтенеченә шундук ризалык күрсәттеләр һәм шуннан соң хезмәтче, якташ егетегез сезгә бик мөһим бер нәрсә хәбәр итәргә теләп, үзен кабул итүегезне сорый, дип де Тревиль әфәндегә әйтергә китте. Бер биш минуттан инде де Тревиль әфәнде кабинетына килде. Д'Артаньяннан: — Минем нинди ярдәмем кирәк, болай соңга калып нинди йомыш белән йөрисең? — дип сорады.

— Гафу итегез, әфәндем! — диде Гасконь егете, кабинетта үзе генә чагында ул сәгатьне унбиш минутка артка чигереп өлгергән иде инде.— Мин сәгать унынчы егерме биш минутта сезнең янга килү әле бигүк соң түгел дип уйлаган идем.

— Унынчы егерме биш минут? — диде де Тревиль, стена сәгатенә таба борылып.— Юк, алай гына булмас!

— Әнә үз күзегез белән күреп ышаныгыз,— диде д'Артаньян.

— Шулай икән шул. Хәзер вакыт соңрактыр дип уйлаган идем мин,— диде де Тревиль.— Миңа нинди йомышыгыз бар соң?

Шуннан соң д'Артаньян ашыкмыйча гына королева турында сөйләргә керешге. Аның хәле турындагы борчулары белән уртаклашты. Бекингэмга каршы кардиналның ниләр эшләве турында ишеткәннәрен әйтте. Егет шулхәтле тыныч һәм шулхәтле ышанып сөйли иде ки — де Тревиль дә аның сөйләгәннәренә ышанмый кала алмады, чөнки, әйткәнебезчә, ул үзе дә кардинал, король һәм королеваның үзара мөнәсәбәтләрендә ниндидер үзгәреш барлыгын сизенгән иде.

Сәгать ун тулгач, д'Артаньян де Тревиль әфәнде белән саубуллашты. Җиткергән хәбәрләре өчен капитан аңа рәхмәт әйтеп, король белән королевага тугрылыклы булып хезмәт итәргә киңәш бирде һәм шуннан соң кунак бүлмәсенә кире кайтты.

Баскычтан төшеп җиткәч, д'Артаньян таягын онытып калдырганлыгын хәтерләде. Шуңа күрә йөгерә-йөгерә кире менде дә кабинетка барып керде, керү белән үк, сәгатьнең артка калганлыгын иртәгә иртән беркем сизмәсен дип, укларын кире үз урынына күчереп куйды. Аның алиби икәнлеген расларлык шаһит барлыгына күңеле тынычланып, ул аска төште дә урамга чыгып китте.

## XI

## ИНТРИГА ТӨЙНӘЛӘ

Де Тревиль әфәнде яныннан чыккач, д'Артаньян, уйларына чумып, өенә кайту өчен иң озын юлны сайлады.

Юлыннан шулхәтле ерак китеп, йолдызларга карап әле елмая, әле авыр сулый-сулый, ниләр уйланды икән Гасконь егете?

Бонасье ханым турында уйлана иде ул. Өйрәнчек мушкетерга бу яшь ханым сөяр өчен идеал бер хатын булып күренде. Шундый чибәр-сөйкемле, бөтенләй серле кебек үзе, король сараендагы барлык интригаларны диярлек белеп тора, шул хәлләр аның сокландгыч матур йөзенә үзенә бертөрле борчу эзләре салган иде. Егеткә ул алай буй-күз җитмәслек бер нәрсә булып тоелмады, бу хәл исә тәҗрибәсез гашыйк егет күз алдында ханымга тагы да әйтеп бетергесез сөйкемлелек өсти иде. Аннан ары, д'Артаньян аны тентергә һәм, ихтимал, газапларга да җыенган дәҗҗаллар кулыннан тартып алды бит, егетнең исә аны шундый хәлдә коткаруы ханымның йөрәгендә рәхмәт хисе тудырды, бу хиснең тиз арада назлырак тойгыларга әйләнеп китүе дә бик ихтимал бит.

Д'Артаньян инде күңеленнән — хыял канатында нинди тиз оча уйлар! — үзе янына яшь ханым исеменнән кеше килүен дә күз алдына китерә. Бу кеше аңа ханымның күрешәсе килүе турында әйткән хатын тапшыра, шуңа өстәп алтын чылбыр белән алмаз кашлы йөзек тә бирә, имеш. Без инде ул замандагы егетләрнең король кулыннан бүләк алган чакта бер дә уңай-

сызланмауларын әйтеп киткән идек. Моңа өстәп тагын шунысын да әйтик: әхлак таләпчәнлеге бик артык булмаган ул заманда егетләр үзләренең сөйгән ярлары каршында да чамадан ашкан горурлык күрсәтмәгәннәр. Дамалары, сөйгән егетләренең бигүк нык булмаган хисләрен ныгытырга тырышканлый, аларга һәрвакыт диярлек истәлеккә озак саклана торган кыйммәтле бүләкләр калдырганнар.

Ул заманнарда ирләр хатын-кыз ярдәмендә үзләренә юл салганнар һәм моннан бер дә хурланмаганнар. Бары тик чибәрлеге булганнары гына үзләренең чибәрлеген бүләк иткәннәр. «Иң гүзәл кыз да үзендә барын гына бирә ала» дигән әйтем дә шуннан калган булса кирәк. Байлары байлыгыннан өлеш чыгарган. Шуңа күрә маҗараларга бай ул чорның — нәр башына сөяркәләре бәйләп җибәргән акча янчыгы белән дәрәҗәгә дә, сугыш мәйданында җиңүгә дә ирешкән байтак каһарманнары бар.

Д'Артаньян ярлы егет иде. Бу Гасконь егетенә өч мушкетер биргән, әхлакка бигүк ярашлы да булып бетмәгән киңәшләр өермәсе провинция кешеләренә хас булган базымсызлык кунычын — нәфис чәчкә сыман, шәфталу җимешенә кунган онта сыман бер нәрсәне — бик тиз очыртып бетерде. Заманының сәер гадәт-йолаларына буйсынган хәлдә, д'Артаньян Парижда үзен дошман басып алган каладагы шикелле, әйтик, Фландриядәге кебек хис кыла: анда испаннар хөкем сөрсә, монда хатын-кыз өстенлек итә иде. Анда да, монда да дошман бар, аның белән көрәшергә кирәк, контрибуция бар — аны түләтергә кирәк.

Шулай да без бер нәрсәне әйтеп китәргә тиешбез: д'Артаньянның күңелен хәзер әчкерсез, саф бер тойгы биләп алган иде. Дөрес анысы, галантерейчы үзенең бай кеше икәнлеген әйткән иде аңа. Бонасье әфәнде шикелле беркатлы ирнең акча янчыгы хатыны кулында булырга тиешлеген төшенүе д'Артаньянга әллә ни кыен булмады. Әмма бу хәл егетнең күңелендә Бонасье ханымны күргәч кузгалган тойгыларына йогынты ясамады, һәм аның йөрәгендә уянган мәхәббәт хисләренә файда дигән нәрсәнең бөтенләй дип әйтерлек катнашы да юк иде. Без «дип әйтерлек» дибез, чөнки сөйкемле, чибәр һәм зирәк акыллы бер хатынның бай да булуы мәхәббәт тойгыларына комачау итми, киресенчә — аны көчәйтә генә төшә.

Матурлыкка ямь өстәп җибәрә торган аристократик бизәнчекләрнең муллыгы байлыкка бәйле. Кар төсле ап-ак юка оек, челтәр яка, нәфис башмак, чәчтәге матур тасма ямьсез хатынны сөйкемле итми, ә менә сөйкемле хатынны тагы да чибәрләндереп җибәрә, кул-беләкләрне әйткән дә юк инде — ни күп отканы — кул. Хатын-кызның куллары матур булсын өчен ул эш эшләмәскә тиеш.

Аннан ары, д'Артаньян,— без аның акча ягын укучыдан яшермәгән идек,— әйе, д'Артаньян миллионер түгел бит. Дөрес, ул кайчандыр киләчәктә миллионер булырга хыяллана, ләкин

андый бәхеткә ирешәсе вакыты, үзе билгеләп куйганча, шактый ерак иде әле. Ә хәзергә — ярабби, сөйгән хатынын, мең төрле бизәнчек булдырырга тели (ул бичараларның бөтен шатлыклары да шул бит), синең исә шул бизәнчекләрне алып бирерлек тә хәлең юк! Хатын-кыз үзе бай булып, сөйгәне ярлы булса, ул, һич югы, егете алып бирә алмаганны үзе сатып ала ала. Боларны ул гадәттә ире акчасына юнәтсә дә, моның өчен иргә бик сирәк рәхмәт әйтәләр.

Д'Артаньян, берәүнең җан сөйгәне булырга хәзерләнсә дә, тугры дус булуын да ташламады. Бөтен күңелен биреп, чибәр Бонасье ханым белән мавыккан чагында дусларын да онытмады. Бонасье ханым Сен-Дени аланында, я булмаса Сен-Жермен ярминкәсендә парлашып йөрерлек бер хатын — шунда Атос, Портос һәм Арамисны да нярту Портос һәм Арамисны да ияртергә була — д'Артаньянның алар алдында егетлек уңышы белән мактанып аласы килә иде. Аннары, озак кына сәйран кылып йөргәннән соң, аппетит та ачылып китә. Д'Артаньян беркадәр вакыттан бирле бу хәлне сизә башлаган иде. Ара-тирә кулынны дустың кулына, аягыңны сөйгәнеңнең аягына тидереп рәхәтләнеп утыра торган аш мәҗлесе дә ясап алырга була. Һәм, ниһаять, бик тә кыен чакларда, бернинди чара калмаганда, д'Артаньян дусларына ярдәм дә итә алачак.

Ә теге Бонасье әфәндене хәле ничек икән соң? Д'Артаньян бит, кара киемле кешеләр алдында аннан ваз кичеп, ә үзенә пышылдап кына: коткарам, ярдәм итәм, ди-ди, аны шымчылар кулына тоттырып җибәргән иде. Укучыларга турысын әйтергә мәҗбүрбез: д'Артаньян аны уена да кертеп карамый, исенә төшсә дә, күңеленнән: кайда булса — шул урынында ята бирсен, дип кенә тели иде. Башка барлык тойгылар арасында мәхәббәт дигәнең иң эгоистик бер тойгы, күрәсең.

Шулай да укучыларыбыз борчылмасын: әгәр д'Артаньян, үзенең фатир хуҗасын онытткан яки, мин аны кая алып киткәнлекләрен белмим дип, онытканга салышкан икән, аны без онытмыйбыз, аның кайда икәнлеге безгә бик билгеле. Ләкин, вакытлыча гына булса да, без Гасконь егетенә ияреп, мөхтәрәм галантерейчыга соңрак әйләнеп кайтырбыз.

Д'Артаньян, мәхәббәт хыялларына бирелеп, төнге күк йөзе белән сөйләшә, йолдызларга карап елмая-елмая, Шерш-Миди, ягъни, ул заманда атап йөртелгәнчә, Шасс-Миди урамы буйлап өскә менеп бара иде. Арамис торган йорт тирәсенәрәк җиткәч, ул дусты янына кермәкче булды, ни өчен «тычкан тозагы»на хәзер үк килеп җит дип Планшены җибәргәнлеген аңлатырга иде исәбе. Әгәр Планше килгәндә Арамис өендә булган булса, ул, һичшиксез, Каберчеләр урамына йөгергән булыр иде һәм анда ике иптәшеннән бүтән кеше күрмәгәч, ни өчен чакырылганлыгын аңламыйча, аптырашта калган булыр иде. Д'Артаньянга ни өчен дустын чакыртканлыгын аңлатырга кирәк иде. Егет үз-үзенә әнә шуны кычкырып әйтте.

Күңеленнән ул дусты янына керүне үзенең йөрәген үк булмаса да, бөтен уйларын билән алган чибәр Бонасье ханым турында сөйләшергә җайлы бер сәбәп дип карый иде. Үз гомерендә беренче тапкыр гашыйк булган кешегә андый нәрсәне эчеңдә генә сакла дип әйтеп булмый шул. Беренче мәхәббәтнең шатлыгы шундый зур, шундый көчле — аны эчеңдә генә тыеп кала алмыйсың, югыйсә гашыйк кеше шул шатлыгыннан шартлап үләр иде.

Париж каласы өстенә төн караңгысы иңгәнгә ике сәгатьләп булды инде, урамнарында кеше-кара күренми башлады. Сен-Жермен бистәсенең барлык сәгатьләре төнге унберне суктылар. Төне җылы, тып-тын. Д'Артаньян хәзер Асса урамы уза торган төштәге тыкрыктан бара иде. Бөтен һава хуш ис белән тулган, ул исне тымызык җил Вожирар урамындагы кечке чык һәм төнге яраудан хушланып калган бакчалардан китерә иде. Еракта, тыгыз тәрәзә капкачлары аша басыла төшеп, ниндидер кабакта кәеф ачучыларның җырлаулары ишетелә иде. Д'Артаньян, тыкрык башына җиткәч, сулга борылды. Арамис торган йорт Кассет урамы белән Сервандони урамы арасына урнашкан иде.

Д'Артаньян, Кассет урамын узгач, дусты йортының ишеген ерактан ук күрде. Йортның ишеге өстендә өрәңге ботаклары, куе кыргый виноград белән аралашып, тыгыз яшел чатыр хасил иткән иде. Шул вакыт д'Артаньянга Сервандони урамыннан бирегә таба ниндидер бер карамчык борылган сыман тоелды. Карамчык дигәне плащка төренгән иде, шуңа күрә д'Артаньян башта аны ир кешедер дип уйлады. Ләкин моның тәбәнәк буйлы булуын, аяк атлавы һәм гәүдә селкенешләре тигезле-тигезсез икәнлеген искәрү белән бу кешенең тәгаен хатын-кыз булуына ышанды. Хатын, эзләгән йортым шушы микән дип шикләнгән сыман башын күтәреп карана-карана, үзенең кай тирәдә булуын чамаларга тырыша, туктый да берничә адым кире китә, аннары тагын килә башлый иде. Д'Артаньянның бу хәлгә күңеле кытыклана башлады.

— Әллә үзенә ярдәм итәсе инде? — дип уйланды егет.— Йөрешенә караганда яшь кенә булырга охшый, чибәрдер дә әле. Әлбәттә! Ләкин бу вакытта кала урамы буйлап йөгереп йөргән бу хатынның сөяркәсе белән очрашырга чыккан булуы да ихтимал бит. Ах, шайтан алгыры! Аларның күрешүенә комачаулау танышу өчен җүнле чара түгел инде.

Ул арада яшь хатын, йортлар һәм тәрәзәләрне саный-саный, якыная башлады. Хәер, аңа йорт, тәрәзәләр санавы әллә ни кыен да түгел, күп вакыт та кирәкми иде. Урамның бу тирәсендә нибары өч йорт бар, һәм нибары ике тәрәзә генә урам якка караган иде. Ике тәрәзәнең берсе — Арамис тора торган флигельгә параллель салынган кечерәк бер бинаныкы, икенчесе — Арамисныкы.

«Валлаһи! — дип куйды д'Артаньян, кинәт теге дин галименең сеңлесен исенә төшереп.— Соңгарып йөри торган бу асыл кош безнең дусның йортын эзләсә, яман кызык булачак. Валлаһи, башымны кисмәгә бирәм — чыннан да, шулай булырга охшый бу. Яхшы, Арамис дус, бу юлы инде мин синнән дөресен әйттермичә калмам».

Һәм Д'Артаньян ниндидер бер куыш сыман җирнең түренә кереп, шунда таш эскәмия янындагы иң караңгы почмакка сыенды.

Яшь хатын якынлаша бирде. Аның яшь булуына инде берничә шик калмады; яшь икәнлеген башта сиздергән йөрешеннән тыш, тавышы да шуны белгертеп тора иде; хатын әкрен генә йөткереп куйды, һәм д'Артаньян аның шул йөткерүеннән тавышы яңгыравыклы яшь тавыш булуын белде. Һәм шундук, бу йөткерү — шартлы бер сигнал булырга тиеш, дип уйлады.

Әллә бу сигналга каршы шундый ук сигнал белән җавап бирделәрме, әллә, ниһаять, хатын чит кеше ярдәменнән башка да максатына җиткәнлеген белдеме — ул кинәт туп-туры Арамис тәрәзәсе янына килде дә, бармагын бөккән килеш, өч тапкыр: шык... шык... шык... иттереп тәрәзә капкачын шакыды.

— Әлбәттә, Арамиска шакый бу! — дип пышылдады д'Артаньян.— Әнә ничек икән эшләр, алдакчы әфәнде! Дин гыйлемен ничек өйрәнгәнегезне белдем мин хәзер!

Яшь хатын капкачны шакуга ук, тәрәзәнең эчке каты ачылды һәм капкач ярыгы аша ут чагылып китте.

— Әһә,— диде тыңлап торучы,— әһә, ишек төбендә булмаса, тәрәзә каршында бер ханым килгәнен көтеп торганнар! Хәзер тәрәзә капкачы ачыла да ханым тәрәзәдән эчкә кереп китә. Бик шәп!

Әмма д'Артаньянның гаҗәбенә каршы, капкач ачылмады. Ярыкта чагылып киткән ут та юкка чыкты, бөтен җир яңадан караңгылыкка чумды. Д'Артаньян, бу хәл озакка бармас, дип уйлады һәм бөтен игътибары белән йотылып көтә башлады.

Хаклы булып чыкты ул. Беравыктан эчке яктан тук-тук итеп ике тапкыр капкачны шакыдылар.

Урамда басып торган яшь хатын моңа каршы бер генә шакыды да, капкач ачылып китте.

Д'Артаньянның шулкадәр дә йотылып карап һәм тыңлап торганын күрсәгез икән!

Бәхетсезлеккә каршы, утны икенче бүлмәгә күчерделәр. Ләкин егетнең күзе карангыга иялэшеп өлгергән иде инде. Аннан тыш, Гасконь кешеләренең күзе, мәче күзе шикелле, төндә дә яхшы күрә, дип сөйлиләр.

Д'Артаньян яшь ханымның кесәсеннән ниндидер ак төргәк чыгарып шуны ашыга-ашыга сүтүен күрде. Кульяулык иде бу. Хатын яулыкны сүтте дә сөйләшеп торган кешесенә яулыкның почмагын күрсәтте.

Д'Артаньян шундук Бонасье ханымның аягы яныннан тап-

кан һәм Арамис җиргә төшергән яулык ише кулъяулыгын күз алдына китерде.

Нинди роль уйнады икән соң ул яулык, шайтан алгыры?

Үзе басып торган төштән Гасконь егетенә Арамисның йөзе күренми иде,— шулай да тәрәзә каршындагы хатын белән Арамис сөйләшкәнлегенә ул бөртек тә шикләнмәде. Кызыксынуы саклану кирәклегеннән көчлерәк булып чыкты һәм, бу вакыйга үзәгендәге ике кешенең бөтен игътибары яулыкта булудан файдаланып, егет яшен тизлегендә куышыннан чыкты да тавыш-тынсыз гына урам аша йөгереп үтеп, стена буена, Арамис бүлмәсенең эчен күрә алырлык төшкә барып сыенды.

Тәрәзәгә күз салгач, д'Артаньян гаҗәпләнүеннән кычкырып җибәрә язды: төнге кунак белән Арамис түгел, бәлки бер хатын-кыз сөйләшеп тора иде. Кызганычка каршы, д'Артаньян караңгыда аның буй-сынын шәйләсә дә, йөзен ачык күрә алмады.

Шул вакыт бүлмәдәге хатын кесәсеннән икенче яулык чыгарып, үзе алган яулык урынына кайтарып бирде. Шуннан соң ике хатын бераз сөйләшеп алдылар. Аннары тәрәзә капкачы ябылды. Урамдагы хатын борылды да, плащ башлыгын йөзенә төшереп, д'Артаньян яныннан өч-дүрт адымда гына үтеп китте. Ләкин аның мондый саклык чарасы күрүе соң иде инде — д'Артаньян Бонасье ханымны танып өлгергән иде.

Бонасье ханым! Хатын кесәсеннән яулык чыгарган чагында ук д'Артаньянның күңеленнән «ул» дигән шик чагылып узган иде. Әмма үзен Луврга озатып куярга дип де Ла Порт әфәндене чакырырга җибәргән Бонасье ханымның шушылай, үзен яңадан урлауларыннан да курыкмыйча, төнге сәгать уникенче яртыда кала урамнарында йөгереп йөрүенә ышануы ифрат кыен иде!

Моны ул, димәк, ниндидер бер зур, зарури эш өчен эшләп. Егерме биш яшьлек хатын өчен ул зарури эш мәхәббәт булмыйча тагын ни булсын икән?

Ләкин ул үзе өченме, әллә өченче бер кеше өченме шундый куркыныч эшкә риза булган? Д'Артаньян үз алдына әнә шул сорауны куйды. Бу хатынның сөяркәсе булып беткән бер кеше сыман, егетнең күңелен көнчелек корты кимерә башлаган иде.

Хәер, Бонасье ханымның кая ашыкканын белер өчен ансат кына чара да бар бит. Артыннан иярәсен дә китәсең. Шулхәтле ансат эш ул — д'Артаньян уйлап та тормастан шул чарага кереште.

Әмма, куыш эченнән таш сын чыккан шикелле, стенадан бер егет аерылганын күреп, аның аяк тавышын ишетүгә, Бонасье ханым кычкырып куйды да йөгерергә кереште.

Д'Артаньян аны куып китте. Плащ итәкләренә бутала-бутала йөгергән хатын-кызның артыннан җитүе әллә ни кыен булмады аңа. Шуңа күрә, хатын икенче урамга борылып, аның очтән берен дә узып өлгермәде — егет аны куып җитте. Бичара

хатын — арудан бигрәк, куркуыннан — тәмам хәлдән тайган иде — д'Артаньян аның җилкәсенә кулын китереп салуга, хатын бер аягы белән җиргә тезләнде дә буылган сыман тавыш белән:

— Теләсәгез — үтерегез! Барыбер берни әйтмәячәкмен! — дип кычкырды.

Д'Артаньян аны, бер кулы белән биленнән алып, җирдән торгызды. Ләкин хатынның бөтен авырлыгы белән беләгенә салынганын тоеп һәм һуштан язып барганлыгын аңлап, егет, үзенең турылыклы булуына ышандырырга тырышып, ханымны тынычландырырга кереште. Тик Бонасье ханым өчен мондый гына вәгъдәнең бәһасе бик аз иде шул: тугрылык вәгъдәсен иң эшәке ният белән дә әйтеп була бит. Әмма бу вәгъдәне әйткән тавыш,— менә кайда иде аның көче. Яшь ханымга бу тавыш бик таныш кебек тоелды. Ул, күзен ачып, үзенең котын алган әлеге кешегә текәлеп карады һәм, д'Артаньянны тануга, шатлыгыннан кычкырып җибәрде.

— Аһ, сез икәнсез! Яраббым, рәхмәтем яусын сиңа! — дип тәкрарлады хатын.

— Әйе, мин бу,— диде д'Артаньян.— Ходай сезне саклар өчен җибәрде мине.

— Шуның өчен генә артымнан күзәтеп килдегезме? — дип хәйләкәр елмаеп сорады яшь ханым — шаяруы инде сизелә дә башлады. Дошманы дип уйлаган кешесе дусты булып чыккач, куркуы да бетте.

— Юк, ихластыр, алай түгел,— диде д'Артаньян.— Мин очраклы рәвештә генә юлыктым сезгә. Бер дустымның тәрәзә капкачын бер хатын шакыганын күрдем дә...

— Бер дустыгызның? — дип, егетне сүзеннән бүлдереп сорады Бонасье ханым.

— Әйе. Арамис — минем иң якын дусларымның берсе.

— Арамис? Кем ул?

— Юкны сөйләмәгез! Арамисны белмим дип, мине ышандырмакчы буласызмы?

— Ул исемне беренче ишетүем.

— Алайса, сезнең бу йортка да беренче килүегезменi?

— Әйе.

— Шунда бер егет яшәгәнне белмәдегезме?

— Юк.

— Мушкетер егет?

— Юк инде, юк!

— Димәк, сез аны эзләмәгәнсез?

— Әлбәттә, шулай. Мин сөйләшкән кешенең хатын-кыз икәнлеген үзегез дә күргәнсездер.

— Анысы дөрес. Ул хатын Арамисның дусты түгелме?

— Белмим.

— Соң, ул хатын шунда яшәгәч инде?..

— Анысы миңа кагыла торган эш түгел.

— Кем соң ул?
— О, ул сер — минем үз серем түгел шул.
— Кадерле Бонасье ханым, сез искиткеч чибәр, шуның белән бергә гаҗәеп дәрәҗәдә серле дә бер хатын.
— Минем өчен начар түгелдер ул?!
— Түгел, билгеле, киресенчә, сез гүзәл.
— Алай булса, кая, кулыгызга таяныйм әле.
— Рәхим итегез. Ә хәзер нишлибез?
— Хәзер мине озатып куегыз.
— Кая?
— Мин кая барсам — шунда.
— Ә сез кая барасыз соң?
— Ишек төбенә хәтле озатып куйсагыз — күрерсез.
— Сезне көтеп торасы да булырмы?
— Анысы бушка көтү генә булыр.
— Димәк, сез кайтканда үзегез генә булмыйсыз?
— Бәлки — шулайдыр, бәлки — түгелдер.
— Ә сезне озатачак кеше — ир-атмы, әллә хатын-кызмы?
— Анысын белмим әле.
— Аның каруы, мин беләчәкмен.
— Ничек итеп?
— Көтеп торам да сезнең кем белән чыкканыгызны күрәм.
— Алайса — хушыгыз!
— Ничек инде ул алай?
— Сезнең миңа бүтән кирәгегез юк.
— Соң, сез бит үзегез үтендегез...
— Мин сездән шымчыларча күзәтеп йөрүегезне түгел, дворяннарча ярдәм итүегезне сорадым.
— Ай-һай, артык каты сүз әйттегез.
— Кешенең үз теләгенә каршы килеп, артыннан күзәтеп йөрүчене кем дип атыйлар соң алайса?
— Тыйнаксыз дип.
— Бик йомшак сүз бу.
— Болай булгач, берни эшләп тә булмый инде, ханым. Сезнең барлык теләкләрегезне үтәргә туры килә.
— Ә нигә сез үзегезне минем ул теләгемне башта ук үтәү егетлегеннән мәхрүм иттегез?
— Ә үкенүдә егетлек юкмыни?
— Чыннан да үкенәсезме сез?
— Үзем дә белмим. Тик бер нәрсәне генә беләм: әгәр дә сез миңа бара торган җирегезгә чаклы озатып куярга рөхсәт итсәгез, мин сезнең бөтен теләгегезне үтәргә әзер.
— Шуннан соң сез мине калдырып китәсезме?
— Әйе.
— Артымнан күзәтеп йөрмисезме?
— Юк.
— Валлаһимы?
— Дворян сүзе!

— Алайса кулыгызны берегез дә — киттек!

Д'Артаньян Бонасье ханымга кулын бирде, һәм яшь ханым, көлеп җибәрергә әзер булып, шулай да әле тәне калтырана-калтырана, егетнең беләгенә тотынды. Шул рәвешчә алар Лагарп урамы очына җиттеләр. Шунда яшь ханым, Вожирар урамындагы шикелле, икеләнебрәк калган сыман булды, аннары кайбер билгеләр буенча кирәкле ишекне эзләп тапты, күрәсең.

— Хәзер инде миңа менә монда керергә кирәк,— диде ул, әлеге ишек янына килеп.— Егетләрчә ярдәм итүегез өчен мең рәхмәт сезгә. Сез мине үзем генә булганда очраячак хәвеф-хәтәрләрдән саклап калдыгыз. Тик шулай да әйткән вәгъдәгезне үтәргә вакыт житте сезгә. Мин үземә кирәк җиргә килеп җиттем.

— Ә кире кайтканда сез хәвеф-хәтәргә юлыкмассызмы соң?

— Караклар очраса гына инде!

— Алар куркыныч түгелмени?

— Минем нәрсәмне таласыннар икән? Янымда бер денье акчам да юк минем.

— Герб сурәте төшерелгән, бик матур итеп чигелгән кулъяулыгыгыз барын онытасыз.

— Нинди кулъяулык ул?

— Мин сезнең аяк очыгыздан табып, кесәгезгә салган яулык.

— Тынычгыз, шым булыгыз, алла бәндәсе! — диде яшь ханым, куркынып.— Әллә сез мине харап итәргә телисезме?

— Үзегез күреп торасыз бит: сезне куркытыр өчен нибары бер сүз дә җиткәч һәм, бу сүзне берәр кеше ишетсә, харап булам, дип үзегез үк әйткәч, сезнең өчен тагын да куркыныч булуы бик ихтимал. Карагыз әле, ханым,— дип, д'Артаньян хатынны беләгеннән тотып алды да аңа ялкынлы күз карашын төбәде,— карагыз әле, булыгыз әле кыюрак, ышаныгыз миңа! Минем йөрәгем сезне ярату, сезгә тугрылык хисләре белән тулганлыгын күзләремнән күреп белмәдегезмени?

— Мин аны тоеп торам. Шуңа күрә сез минем үземнең бөтен серләремне сораша аласыз, әмма чит кеше сере — анысы башка нәрсә.

— Яхшы,— диде д'Артаньян,— мин аларны чишәчәкмен. Ул серләр сезнең язмышыгызга кагылуы ихтимал икән, ул чагында минем өчен дә уртак булырга тиеш алар.

— Берүк ходай саклый күрсен сезне ул эштән! — диде яшь ханым, һәм, тавышында шундый зур борчу-шом ишетелеп, д'Артаньян ихтыярсыздан калтыранып куйды.— Зинһар, үтенеп сорыйм сездән: миңа кагылышлы нәрсәләрнең берсенә дә кысылмагыз, үземә йөкләнгән бурычны үтәгәндә миңа ярдәм итәргә тырышмагыз. Мин моны сезнең миңа карата булган хисегез хакына, гомеремдә дә онытмаслык ярдәмегез хакына үтенеп сорыйм, ихластыр. Моннан ары минем хакта бүтән

уйламагыз, сезнең өчен дөньяда мин юк, мине бөтенләй күргәнегез дә юк дип белегез.

— Арамис та минем шикелле булырга тиешме? — дип сорады д'Артаньян, ханымның бу сүзләренә үртәлеп.

— Менә инде сез икеме-өчме тапкыр шул исемне телгә алдыгыз, әфәндем. Югыйсә мин сезгә, аны белмим, дип әйттем бит инде.

— Үзегез аның тәрәзәсен килеп шакыйсыз, үзегез шул кешене белмисезме? Нәрсә сез, ханым! Әллә сез мине бик беркатлы бер кешегә саныйсызмы?

— Дөресен әйтегез: сез бу хәлләрне үз башыгыздан гына уйлап чыгардыгыз бит, Арамис дигәнен дә мине ихлас күңелдән сөйләштерү өчен генә уйлап таптыгыз.

— Мин бер нәрсә дә уйлап чыгармадым, ханым, бер нәрсә дә уйлап тапмадым. Чын дөресен сөйлим.

— Дусларыгыздан берсе шул йортта тора дисезме инде?

— Әйе, шулай дим һәм өченче тапкыр кабатлап әйтәм: ул йортта минем дустым тора, исеме аның — Арамис.

— Вакыты җиткәч, барысы да ачыкланыр, ә хәзергә шым булыгыз, әфәндем! — диде яшь ханым пышылдап кына.

— Әгәр дә сез минем сезнең каршыгызда ачылган йөрәгемдәниләр барлыгын укып белә алсагыз, шундый кайнар кызыксыну күреп, мине кызганыр идегез, шулкадәр кайнар мәхәббәт күреп, шул минутта ук бу кызыксынуны канәгатьләндерер идегез. Үзегезне яраткан кешедән куркырга кирәкми,— диде д'Артаньян.

— Ярату турында бик тиз тел ачтыгыз әле сез,— диде яшь ханым, башын чайкап.

— Мәхәббәт тойгысы бик тиз һәм беренче тапкыр уянды миндә. Миңа егерме яшь тә тулмаган бит әле.

Бонасье ханым күз кыры белән генә егеткә карап алды.

— Карагыз әле, мин бит моның эзенә төштем инде,— диде д'Артаньян.— Моннан өч ай элек мин бер яулык аркасында Арамис белән дуэльдә сугыша язган идем. Ул яулык аның йортындагы хатынга сез күрсәткән яулык төсле иде, шундый ук гербы да бар иде.

— Валлаһи дип әйтәм, әфәндем, болай төпченеп сез минем теңкәмә тиясез,— диде яшь ханым.

— Әй ханым, үзегез шундый сак хатын, әгәр үзегезне кулга алганда шундый яулык тапсалар, бу хәл сезне фаш итмәс идеме?

— Нигә? Инициаллар минеке түгелмени? «К. Б.», Констанция Бонасье.

— Яки Камилла де Буа-Траси.

— Тыныгыз, әфәндем! Тыныгыз! Әгәр миңа куркыныч булу ихтималы гына сезне туктатмый икән, ул чагында үзегезгә куркыныч килү ихтималын да уйлагыз.

— Миңамы?

— Әйе, сезгә. Минем белән танышуыгыз өчен сезне төрмәгә ябулары яки үтереп китүләре ихтимал.

— Алайса моннан соң мин сездән бер адымга да аерылмыйм!

— Әфәндем,— диде яшь ханым, ялварган бер кыяфәт белән кулларын кыскалап.— Әфәндем, гаскәри намусына, дворян мәрхәмәтлелегенә мөрәҗәгать итеп инәлеп сорыйм — китегез! Ишетәсезме: инде төн уртасы җиткән, бу вакытта мине көтеп торалар.

— Ханым,— диде д'Артаньян баш иеп,— шулкадәр ялварып сораган кешенең гозерен кире кага алмыйм. Тыныч булыгыз, мин китәм.

— Сез минем артымнан бармассызмы, иярәп йөрмәссезме?

— Мин хәзер үк өемә кайтып китәм.

— Һай, намуслы егеттер дип уйлаган идем шул мин сезне! — диде Бонасье ханым, бер кулын егеткә сузып, икенчесе белән таш стенага уелган кечерәк бер ишек янындагы чүкечкә үрелде.

Д'Артаньян үзенә таба сузылган кулны эләктереп алды да кайнарланып иреннәрен тидерде.

— Моннан ары гомеремдә дә бүтән күрмәсәм иде сезне! — диде егет, беркадәр дорфарак итеп. Мондый дорфалык еш кына хатын-кызга купшы мактау сүзләренә караганда күбрәк ошый, чөнки мондый чакта кешенең күңел төбенә күз салырга мөмкин, бу — хис-тойгының акылны басып китү билгесе.

Бонасье ханым д'Артаньянның кулын кысты да (егет аның кулын һаман җибәрми тора иде әле) ягымлы диярлек бер төс белән:

— Юк, мин алай дип әйтә алмыйм: бүген булмый калганның киләчәктә булып куюы бик ихтимал,— диде.— Кем белгән бит, әгәр дә мин берәр вакыт үз иркемдә була алсам, шул чагында сезнең кызыксынуыгызга каршы җавап бирә алмаммы...

— Һай, мәхәббәтем, ул да андый өмет белән юана алырмы? — дип дәртләнеп әйтеп куйды егет.

— О, бу хакта мин вәгъдә биреп куя алмыйм. Анысы инде сезнең минем күңелемә нинди тойгылар сала алуыгызга карап.

— Димәк, хәзергә әле, ханым...

— Хәзергә әле, әфәндем, минем күңелемдә рәхмәт тойгысы гына бар.

— Сез артык мәрхәмәтле икәнсез, минем яратуымнан үзегезчә файдаланасыз,— дип ямансылап әйтеп куйды д'Артаньян.

— Юк, әфәндем, мин сезнең намуслы булуыгыздан гына файдаланам. Ләкин ышаныгыз: биргән вәгъдәсен онытмый торган кешеләр дә була дөньяда.

— О, сез мине дөньяның иң бәхетле кешесе итәсез! Онытма күрмәгез бу кичне, онытмагыз шушы вәгъдәгезне!

— Борчылмагыз. Вакыты җиткәч, мин барысын да исемә төшерермен. Хәзер инде, алла хакы өчен, кайтып китегез! Мине нокъ сәгать уникегә көтеп торалар иде, менә хәзер сонга да калам инде.

— Биш минутка сонгарасыз.

— Кайвакыт биш минут биш гасырга да торырлык була.

— Яныш сөйсән.

— Ә сезгә кем әйтте: бу эш бер мәгъшукка бәйләнешле түгел дип?

— Сезне бер ир көтә икән! Бер-ир көтә! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян.

— Менә, безнен бәхәс яңадан башлана инде,— диде Бонасье ханым, көлемсерәп, шул ук вакытта чыраеннан түземсезләнүе дә сизелеп тора иде.

— Юк, юк! Мин китәм, китәм. Мин сезгә ышанам, мин сезнен җаным-тәнем белән тугры булуыма ышануыгызны телим — гәрчә бу тугрылыгым диваналык дәрәҗәсенә җитә язса да. Хушыгыз, ханым, хушыгыз!

Егет, ханымнын кулын үз кулыннан ычкындырырга башкача әмәле калмагандай, каныл гына талпынып аерылды да йөгереп китеп тә барды. Ул арада Бонасье ханым, кулына чүкеч алып, бая тәрәзәне шакыган төсле ук, ишекне какты: салмак-салмак итеп өч тапкыр шакылдатты. Д'Артаньян урам чатына җиткәч борылып карады. Ул арада инде ишек ачылып ябылган, галантерейчынын сөйкемле хатыны юкка чыккан иде.

Д'Артаньян кайтуында дәвам итте. Ул Бонасье ханым артыннан күзәтеп йөрмәскә дип сүз бирде, хәтта үзенен яшәүяшәмәве Бонасье ханымнын кая баруына яки аны кем озатуына бәйле булса да, ул, туры өемә кайтам дип ышандыргач, барыбер шулай эшләячәк иде. Кайта башлаганнан бирле биш минут та үтмәгәндер — ул Каберчеләр урамына да җитте.

«Бичара Атос! Бу эшләрнен берсен дә анламый шул ул,— дип уйланды д'Артаньян.— Я ул мине көтә торгач йоклап киткәндер, я өенә кайтып киткәндер, өенә кайткач инде анда хатын-кыз булганлыгын белгәндер. Атос янына хатын-кыз килгән! Хәер, хатын-кыз бит Арамиста булган. Бик гаҗәп хәл бит әле бу, азагы ни булып бетәчәген бик беләсе иде».

— Начар, әфәндем, бик начар! — дигән тавыш ишетелүгә, д'Артаньян монын Планше икәнлеген танып алды.

Болай килеп чыгуының сәбәбе шул: д'Артаньян, бик борчуга сапкан кешеләр шикелле, үзалдына сөйләнеп кайта торгач, үзе яшәгән йортнын подъездына килеп кергәнен сизми дә калды. Ишектән бераз түрдәрәк анын квартирына баскыч менеп китә иде.

— Ничек ул — начар? Монын белән нәрсә әйтмәкче буласын, тиле? Ниләр булды монда? — дип сорады д'Артаньян.

— Төрле бәла-казалар.

— Нинди бәла-казалар?

— Иң элек, Атос әфәндене кулга алдылар.

— Кулга алдылар? Атосны кулга алдылар? Ни өчен?

— Аны сезнең квартирда туры китергәннәр. Сез дип белгәннәр аны.

— Кемнәр кулга алган соң аны?

— Стражниклар. Сез куып җибәргән теге кара киемле кешеләр аларны ярдәмгә алып килгәннәр.

— Нигә ул үзенең исемен әйтмәгән соң, нигә ул бу эшкә бернинди катнашым юк дип аңлатып бирмәгән?

— Алай һич эшли алмас иде ул, әфәндем. Шулай итәсе урында ул миңа якынрак килде дә пышылдап кына әйтте: «Хәзер миннән бигрәк синең хуҗаңа иректә булу кирәк, ди. Ул бөтен хәлне белә, ә мин берни белмим, ди. Аны кулга алынган дип уйласыннар, шуның белән вакыт отып эшен эшләячәк, ди. Өч көннән соң мин аларга үземнең кем икәнлегемне әйтермен, шуннан соң мине чыгарып җибәрергә тиеш булырлар»,— ди.

— Браво, Атос! Изге җан икән! — дип пышылдады д'Артаньян.— Мондый эшне ул гына булдыра ала. Стражниклар нишләделәр соң?

— Дүртесе аны алып киттеләр, кая алып киткәннәрдер,— Бастилиягәме, Фор-Левеккамы — әйтә алмыйм. Икесе кара киемле кешеләр белән монда калды. Алары бөтен квартирны актарып, барлык кәгазьләрне җыеп алып киттеләр. Шул вакытта икесе ишек төбендә сакта торды. Аннары, эшләрен бетергәч, бөтен өй эчен туздырып, ишекләрне шар ачык калдырып китеп бардылар.

— Ә Портос белән Арамис?

— Мин аларны монда күрмәдем, монда килмәделәр алар.

— Аларның менә хәзер шушы минутта килеп керүләре ихтимал. Минем аларны көткәнлегемне син аларга тапшырырга кушкансыңдыр бит?

— Әйе, куштым, әфәндем.

— Яхшы. Ул чагында син монда торып тор. Әгәр алар килеп керсә, хәлне сөйләп бирерсең. Мине «Нарат күркәсе» мәйханәсендә көтсеннәр. Аларга монда калу җүнлегә булмас. Ихтимал, безнең йортны күзәтеп торалардыр. Мин хәзер де Тревиль әфәнде янына йөгерәм. Аңа хәлне сөйләп бирәм дә мәйханәгә алар янына барам.

— Тыңлыйм, әфәндем,— диде Планше.

Д'Артаньян, чыга башлаган җиреннән кире килеп:

— Син бит инде монда торып торасың? Курыкмассыңмы? — дип сорады, хезмәтчесенә рух бирергә тырышып.

— Анысы өчен борчылмагыз, әфәндем,— диде Планше.— Сез мине белеп бетермисез әле. Тырышсам, мин батыр да була беләм, ихластыр. Бөтен хикмәт тырышуда гына. Аннан ары, мин бит Пикардия кешесе.

— Алайса, хәл иттек,— диде д'Артаньян.— Син үлсәң үләрсең, әмма постыңны ташлап китмәссең — шулаймы?

— Шулай, әфәндем. Хуҗама тугрылыгымны күрсәтергә кирәк булганда мин эшли алмастай нәрсә юк ул.

«Бик шәп! Бу егеткә карата кулланган чарам бик уңышлы булып чыкты шикелле. Кирәк чагында аннан файдаланырга булыр»,— дип уйланды д'Артаньян һәм, көн буе йөгереп йөреп аяклары шактый талган булса да, бар көченә Иске Күгәрчен оясы урамына таба җилдерде.

Тик де Тревиль әфәнде өендә туры килмәде. Аның ротасы Луврда каравыл тора. Ротасы белән бергә ул үзе дә шунда иде.

Әмма, де Тревиль әфәнде янына барып, булган хәлләрне сөйләп бирергә кирәк иде.

Д'Артаньян Луврга үтеп булмас микән дигән карарга килде. Дезэссар әфәнде ротасындагы гвардияче формасы пропуск булып хезмәт итәргә тиеш иде.

Ул Пти-Огюстен урамы буйлап узды, аннары, Яңа күпер аша чыгарга исәпләп, яр буенча китте. Башында, паромга утырып чыгарга кирәк, дигән уй чагылып узды, ләкин, елга буена төшкәч, кулын кесәсенә тыгып караса — паромга түләрлек акчасы юк иде.

Генего урамына җиткәч, кинәт аның күзенә Дофина урамы чатыннан чыгып килгән ике кеше чалынды. Аларның берсе ир кеше, икенчесе хатын-кыз иде. Бу ике кешенең килеш-кыяфәтләре кай яклары беләндер д'Артаньянга гаҗәп тоелды.

Хатын-кызы буй-сыны белән Бонасье ханымны хәтерләтә, ир кеше исә гаҗәп дәрәҗәдә Арамиска охшаган иде.

Өстәвенә, бу хатын кара япанчага төренгән иде — аның бу кыяфәте д'Артаньянның хәтеренә әкъ Вожирар урамындагы тәрәзә яктысында һәм Лагарп урамындагы ишек янында күргәнчә кереп калган иде. Ир кеше исә мушкетер киеменнән иде.

Хатын япанча башлыгын аска ук төшереп битен томалаган, ир кеше йөзен кулъяулыгы белән каплаган. Аларның болай итүләре үзләрен кешеләргә танытмаска тырышуларын әйтеп тора иде.

Алар күпердән бара башладылар. Д'Артаньянның да, Луврга керергә исәп иткәч, юлы күпер аша уза иде. Егет тегеләр артыннан иярде.

Шул хәлендә ул ун адым җир дә китмәде — әлеге хатынның Бонасье ханым, ә ир кешенең Арамис икәнлегенә тәмам ышанды.

Көнчелектән күңелендә туган шик-шөбһә, вәсвәсәләре шул минутта ук яңадан баш калкыттылар.

Димәк, аны алдаганнар, аны дусты алдаган, сөяркәсе итеп ярата башлаган хатын алдаган. Бонасье ханым, Арамисны белмим, дип егет алдында ант итеп әйткән иде бит, ә менә барлы-юклы чирек сәгать тә үтмәгәндер — ул инде Арамис белән култыклашып бара.

Д'Артаньян сөйкемле галантерейчы хатыны белән танышканлыгына әле нибары өч көнә сәгать икәнен, ханымның үзен урларга җыенган шымчылар кулыннан коткарган өчен рәхмәт хисеннән гайре егет белән әле бернинди тойгы уртаклыгы юклыгын һәм Бонасье ханым аңа бернинди вәгъдә бирмәгәнлеген дә уйламады хәтта. Ул үзен рәнҗетелгән, алданган һәм мыскыл ителгән бер мәгъшук итеп хис кылды. Аның ачуыярсуы котырып китте, битенә кан йөгерде. Егет дөресен белергә карар итте.

Яшь ханым белән аның юлдашы, үз артларыннан кемдер күзәтеп килүен сизеп, кызурак атларга керештеләр. Д'Артаньян йөгерә-атлый аларны узды да, кире борылып, алар белән Самаритянка сыны турысында кара-каршы очраштылар. Таш сынны һәм күпернең шул тирәдәге өлешен фонарь уты яктыртып тора иде.

Д'Артаньян тегеләр каршына килеп туктады, ир кеше белән яшь ханым да туктарга мәҗбүр булдылар.

Мушкетер, бер адым артка чигенеп:

— Ни йомыш, әфәндем? — дип сорады. Аның чит миллэт кешесе кебек сөйләшү рәвеше д'Артаньянны алдан юрап куйган фикеренең бер өлеше, һәрхәлдә, ялгыш икәнлеген төшенергә мәҗбүр итте.

— Арамис түгел ич бу! — дип кычкырып әйтеп куйды егет.

— Әйе, әфәндем, Арамис түгел. Гаҗәпләнүегезгә караганда, сез мине икенче бер кеше дип белдегез, шуның өчен мин сезне гафу итәм.

— Сез мине гафу итәсез? — диде д'Артаньян.

— Әйе, — диде ят кеше. — Сезнең миңа йомышыгыз булмагач, үтеп китәргә рөхсәт итегез.

— Сүзегез хак, әфәндем, минем сезгә бернинди йомышым юк. Тик сезнең яндагы ханымга йомышым бар минем, — диде д'Артаньян.

— Минем яндагы ханымга? Сез аны белмисез бит! — диде ят кеше, гаҗәпләнеп.

— Хаталанасыз, әфәндем, беләм мин аны.

— Аһ, — дип куйды Бонасье ханым, шелтәле бер тавыш белән, — сез миңа дворян һәм хәрби кеше буларак сүз бирдегез, мин сезнең намуслы булуыгызга ышана алырмын дип уйлаган идем!

— Ә сез, ханым, сез... — дип уңайсызланып мыгырдады д'Артаньян, — сез дә бит миңа вәгъдә иткән идегез...

— Минем беләккә тотыныгыз, ханым, киттек, — диде чит ил кешесе.

Д'Артаньян, мингерәүләнгән, аптырашта калган бер хәлдә, кулларын күкрәгенә кушырып, Бонасье ханым белән аның юлдашы каршында басып тора бирде.

Мушкетер алга табарак атлады да кулы белән д'Артаньянны бер читкә этәрде.

Д'Артаньян, арткарак чигенеп, кылычын суырып алды. Ят кеше дә ялт кына кылычын чыгарды.

Бонасье ханым:

— Алла хакы өчен, милорд! — дип кычкырып җибәрде дә ике ир арасына ташланып, куллары белән кылычларына үреләбашлады.

— Милорд! — дип куйды д'Артаньян, аңышып.— Милорд!.. Кичерегез, әфәндем... Сез әллә...

— Милорд — герцог Бекингэм,— диде Бонасье ханым әкрен генә.— Хәзер безнең барыбызны да харап итүегез мөмкин.

— Милорд, сез дә, ханым, үтенәм сездән, гафу итегез, кичерегез мине! Мин бит бу ханымны ярата идем, милорд, көнләшәм дә. Сез инде, милорд, мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләсездер. Кичерегез мине, аннары әйтегезче: сез галиҗәнап хакына җанымны бирү кирәк түгелме?

— Сез намуслы егет,— дип, герцог д'Артаньянга кулын сузды, егет ихтирам белән аның кулын кысты.— Сез миңа үз тарафыгыздан ярдәмегезне тәкъдим итәсез — кабул итәм мин аны. Луврга чаклы озатып куегыз безне. Артыбыздан берәрсе күзәтеп килгәнен сизсәгез, үтерегез ул кешене.

Д'Артаньян, ялангач кылычын кулына тотып, Бонасье ханым белән герцогны егерме адым чамасы алгарак уздырып җибәрде дә, Карл I нең ак сөякле гүзәл министры боерыгын төп-төгәл үтәргә әзер булып, алар артыннан атлады.

Тик, бәхеткә каршы, бу кичне батыр егеткә үзенең тугрылыгын эше белән күрсәтергә туры килмәде. Шулай итеп, яшь ханым белән мәһабәт мушкетер тыныч кына Луврга килеп җитеп, Эшель урамы каршындагы ян капкадан эчкә кереп киттеләр. Д'Артаньянның үзенә килгәндә исә, ул ашыгып кына «Нарат куркәсе» мәйханәсенә китеп барды, чөнки анда аны Портос белән Арамис көтеп тора иде.

Ә хәзер, хикәябез белән мавыгып китеп, өч дустыбызны өйләренә кайтарып җибәрик тә Лувр эчендәге бормалы-сырмалы юллар буйлап герцог Бекингэм белән аның юлдашы теге яшь ханым артыннан иярик.

## *XII*

## *ДЖОРДЖ ВИЛЛЬЕ, ГЕРЦОГ БЕКИНГЭМЛЫ*

Бонасье ханым белән герцог Бекингэм Луврга кергәндә әллә ни кыенлыкка очрамадылар. Бонасье ханымны королева штатындагы бер кеше дип беләләр, герцог исә де Тревиль әфәнде мушкетерлары киемен кигән, де Тревиль әфәндене ротасы, әйткәнебезчә, бу кичне король сараенда сакта тора иде. Хәер, Жермен королевага баш-аягы белән турылыклы булып хезмәт итә, берәр хәл була калса, Бонасье ханымны Луврга үзенең сөяркәсен алып кергән дип кенә гаепләрләр. Шуның белән

эш бетәр иде. Бонасье ханым гөнаһны үз өстенә алыр; дөрес, анысы, аның абруйлы намена тап төшми калмас иде, әмма дөньяны үз кулларында тотучы кодрәт ияләре өчен ниндидер бер бичара галантерейчы хатынының абруйлы наме берни дә түгел бит!

Сарай эченә кергәч, герцог белән Бонасье ханым егерме биш адымнар чамасы таш койма буйлап бардылар. Шуннан соң Бонасье ханым көндез ачык булып, төнгә бикләнә торган кечерәк бер ишекнең тоткасына басты. Ишек ачылды. Эчкә кerделәр. Бөтен җир дөм-караңгы булса да, Бонасье ханым Луврның сарай хезмәтчеләре өчен билгеләнгән бу өлешендәге барлык юлларны, аралыкларны белеп бетергән иде. Кергән ишекне бикләгәч, Бонасье ханым герцогны кулыннан җитәкләде дә сакланып кына берничә адым алга атлады, баскыч култыксасына тотынып, аягы белән басманы капшап тапкач, баскычтан менә башлады. Герцог аның артыннан иярде. Өченче катка менеп җиттеләр. Шунда Бонасье ханым, уңга борылып, юлдашын озын гына коридор буйлап алып китте, аннары бер катка кире төшеп, тагын берничә адым атлагач, бер ишекнең йозагына ачкыч тыгып ишекне ачты да төнге лампа белән генә яктыртылган бер бүлмәгә герцогны этәреп кертеп җибәрде.

— Шушында торып торыгыз, милорд. Хәзер килерләр,— дип пышылдады ханым.

Шулай дигәч, әлеге ишектән кире чыкты да бүлмәне бикләп алды, шул рәвешчә герцог чын мәгънәсендә әсирлеккә төште.

Шунысын да әйтми китеп булмый: герцог Бекингэм, япаялгызы калуына карамастан, курку дигән нәрсә тоймады. Аның иң күркәм характер сыйфатларыннан берсе — маҗара эзләү һәм романтика яратуы иде. Ир йөрәкле, кыю һәм эшлекле бер кеше буларак, мондый куркыныч хәлдә беренче тапкыр гына калуы түгел иде. Аны ашыгып Парижга килергә мәҗбүр иткән Анна Австрияленең хаты ялган хат булып, аны тозакка төшерергә тиешлеге герцогка билгеле иде инде. Ләкин Лондонга кайтып китәсе урында ул, әлеге хәлдән файдаланып, королевага сезнең белән көрешмичә китмим дигән сүзен җиткерүләрен үтенде. Королева башта күрешүдән катгый баш тартты, аннары, герцогның шушы сәбәпле берәр төрле акылсызлык эшләп ташлавыннан куркып, аны кабул итәргә һәм герцогның хәзер үк кайтып китүен үтенергә булды. Әмма королева шундый карарга килгән кичне көтелмәгәндә Бонасье ханымны урладылар — герцогны алып килеп, Луврга кертү эше аңа йөкләнгән иде. Бонасье ханымга ни булганлыгын ике көн буе беркем белмәде, эш туктап калды. Әмма Бонасье ханым иреккә чыгып, де Ла Порт белән күрешкәннән соң, эш яңадан хәрәкәткә килде, һәм шул ханым, урланмаган булса, моннан өч көн элек үк башкарып чыгасы бу хәтәр эшне азагына илтеп җиткерде.

Герцог, бер ялгызы калгач, көзге каршына килде. Мушкетер киеме бик килешеп тора иде аңа.

Герцог Бекингэмга утыз биш яшь иде, бөтен Франция белән Англиядә дә ул иң чибәр вельможа, иң нәзакәтле кавалер дигән данны юкка гына тотмый иде шул.

Ике корольнең иң яраткан ышанычлы кешесе, әллә ничә миллион байлыкның хуҗасы, үз илен үзе теләгәнчә әле тынгысызлап, әле тынычландырып, чиксез хакимлектән файдаланучы һәм фәкать үз капризларына гына буйсынучы Джоржд Виллье, герцог Бекингэмлы, хәтта берничә гасырдан соң кешеләрне шаккатырырлык, экиятләрдәгечә бер тормыш белән яши иде.

Үз-үзенә бик нык ышанган, башкалар өчен мәҗбүри булган законнар миңа карамый дип санаган һәм үзенең куәт-кодрәтенә инанган бер хәлдә, ул башка кешеләр өчен уйга да китермәслек бик биек һәм күз камаштыргыч булып тоелырдай максатына да туп-туры бара иде. Менә шулар барысы аңа буй һәм күз җитмәс гүзәл Анна Австрияле белән ничек тә очрашырга һәм аны гашыйк итеп, йөрәгендә мәхәббәт тойгылары уятырга дигән бер кыюлык бирде.

Шулай итеп, әйткәнебезчә, Джордж Виллье көзге каршына килеп басты. Мушкетер эшләпәсе авырлыгыннан басыла төшкән бик матур алтын-сары чәчләрен төзәткәләп, мыегын бөтереп җибәргәч, зарыгып көткән минутының якынлашуына сөенеп, үзен бәхетле һәм горур хис кылып, ул горурлык һәм өмет тулы бер төс белән көзгедәге шәүләсенә елмаеп куйды.

Нәкъ шул минутта стена тышламасына яшереп эшләнгән ишек ачылып китеп, бүлмәгә бер хатын-кыз килеп керде. Герцог аны көзгедән күреп алды да аһылдап куйды — керүче хатын королева үзе иде!

Анна Австриялегә бу вакытта егерме алты-егерме җиде яшьләр чамасы булып, аның иң матур, иң чибәр чагы иде. Йөреше аның королеваларча яки алиһәләрчә иде. Зөбәрҗәт ташы төсле нурланып торган наз һәм галилек тулы күзләре камил бер гүзәллек чагылышы сыман иде.

Австриядәге король нәсел-нәсәбенә хас булганча, аскы ирененең беркадәр бүлтәебрәк торуы да кечкенә генә җете алсу авызын ямьсез итеп күрсәтми,— елмайган вакытында ул искиткеч сөйкемле булып, чибәрләнеп китә, эмма, кирәк чагында, йөзенә тирән бер илтифатсызлык галәмәтләре дә чыгара белә иде.

Тәне аның бәрхет кебек нәфис, йомшак; беләкләре, кулбашлары рәссам сызгандай искиткеч матур — аның бу сыйфатларын шул заманның барлык шагыйрьләре дә шигырьләрендә мактап язалар. Инде килеп, үсмер кыз чагында аксыл сары булып, тора-бара коңгыртлана төшкән, беркадәр пудралаган бөдрә чәчләре ике яктан йөзен каймалап алып соклангыч бер ямь биреп тора,— иң талымлы тәнкыйтьче дә бары тик аның йөз бизәкләре ул кадәр үк җете булмавын, иң таләпчән сынчы

нсә борынының тагы да нәфисрәк була төшүен генә теләр иде.

Герцог Бекингэм, бу матурлыкка сокланып, бер мизгел катып калды: моңарчы Анна Австрияленең бал, бәйрәм һәм күңел ачу кичәләрендә менә хәзерге кебек, гади ак ефәк күлмәктән, король көнчелегенең һәм кардинал Ришелье мәкеренең корбаны булып җитмәгән бердәнбер испан затлы асравы доньяя Эстефанияне нәртеп, шушы бүлмәгә килеп кергәндәге кебек искиткеч чибәр, гүзәл булып күренгәне юк иде әле.

Анна Австрияле бер-ике адым герцогка таба атлады. Бекингэм аның аягына егылды да, королева комачаулап өлгергәнче, аның күлмәк итәген тотып иреннәренә тидерде.

— Герцог, теге хатны мин яздырмаганны беләсездер инде сез?

— Әйе, ханым, әйе, олуг ханым! — диде герцог, дулкынланып.— Мәрмәр ташына җан керер, кардан җылы чыгар дип ышанып, үземнең акылсыз вә ахмак булуымны беләмен. Тик ни чара кылыйм соң: үзең яратканда үзеңне дә яраталар дип бик тиз ышанасың икән. Сезне күрә алгач, минем бу сәяхәтем бушка булмады инде.

— Анысы шулай,— диде Анна Австрияле,— ләкин минем сезнең белән күрешергә ни өчен риза булуым сезгә мәгълүм бит. Минем кайгы-хәсрәтемне аңларга теләмичә, сез бу шәһәрдән китүдән баш тартып килдегез, гәрчә монда калып сез гомерегезне кыл өстенә куясыз һәм мина да намусыма тап төшерү куркынычы китерәсез. Мин шуны әйтер өчен сезнең белән күрешергә риза булдым: бөтен-бөтен нәрсә безнең арада киртә булып тора — тирән диңгезләр дә, дәүләтләребез арасындагы дошманлык та, биргән антларыбызның изгелеге дә. Изгене хурлау — боларның барысына каршы көрәшү ул, милорд! Ниһаять, мин сезнең белән тагын шуны да әйтер өчен күрешергә риза булдым: моннан ары без сезнең белән бүтән очрашырга тиеш түгелбез.

— Сөйләгез, ханым, сөйләгез, королева! — диде Бекингэм.— Сезнең нәфис тавышыгыз сүзләрегезнең рәхимсезлеген йомшарта... Сез изгене хурлау турында әйтәсез. Ходай бер-берсен сөю өчен яраткан йөрәкләрне аеру да изгене хурлау була бит!

— Милорд, исегездән чыгарасыз: моңарчы минем сезне яратам дип әйткәнем булмады! — диде королева.

— Моңарчы сезнең мине яратмыйм дип тә әйткәнегез булмады бит. Ихластыр, андый сүз әйтү — сез олуг ханым тарафыннан бик зур шәфкатьсезлек булыр иде. Әйтегез әле: миндәге шикелле, аерылышу, вакыт аралары, өметсезлек тә сүрелдерә алмаган мәхәббәтне каян таба аласыз сез? Җиргә төшеп калган тасма кисәгенә, уйчан күз карашына, көтелмәгәндә әйтелгән бер сүзгә дә риза булырдай мәхәббәтне каян табасыз? Ханым, минем сезне беренче тапкыр күрүемә менә өч ел булды,

мена өч ел буе мин сезне энә шулай сөям. Телисезме, мин сезгә беренче тапкыр күрүемдә ничек киенгән булуыгызны әйтеп бирәм? Телисезме, хәтта күлмәгегезнең бизәкләренә хәтле тәфсилләп бирәм?.. Менә хәзергедәй күз алдымда сез. Сез, испаннар гадәтенчә, мендәргә утырган идегез. Өстегездә көмеш вә алтын белән укалап чиккән атлас күлмәк иде, асылынып тора торган киң җиңнәре терсәктән өскәрәк күтәрелеп, эре асылташ каптырмалар белән каптырып куелган, менә бу матур куллагыгыз, бу искиткеч беләкләрегез ачылып калган иде. Муеныгызны челтәрле рюшь каплап тора иде. Башыгызда күлмәгегез төсендәге кечкенә генә калфак, калфагыгызга челән каурые кадалган иде. Аһ, аһ, күземне йомсам — мин сезне нәкъ шул чагыгыздагы төсле итеп күрәм, күземне ачсам — менә хәзергечә итеп, ягъни йөз тапкыр гүзәлрәк итеп күрәм!

— Нинди акылсызлык! — дип пышылдап әйтеп куйды Анна Австрияле, үзенең сурәтен бик кадерле, газиз бер хатирә итеп күңелендә саклаганы өчен герцогны ачуланырга йөрәге җитмәде.— Файдасыз хисләрне шундый хатирәләр белән тергезеп яшәү никадәр акылсызлык!

— Башкача ни белән яшим соң мин? Шул хатирәләрдән башка минем бер нәрсәм дә юк бит! Алар минем бәхетем, минем байлыгым, өметем. Минем сезнең белән һәр күрешүем — күңел хәзинәмә сала торган асылташ ул. Бүгенге күрешүебез — сез җиргә ташлап, мин табып алган дүртенче асылташ булыр. Ханым, өч ел буена мин бит сезне нибары дүрт кенә тапкыр күрдем: беренче күрүемне әле яңа гына әйттем, икенче тапкыр мин сезне де Шеврез ханымнарда күрдем, өченче тапкыр Амьен бакчаларында...

— Герцог,— дип пышылдады королева кызарынып китеп,— ул кичне искә төшермәгез!

— Һай, юк, киресенчә: искә төшерик без аны, ханым! Минем гомеремдә иң бәхетле, иң шатлыклы бер кич булды ул. Хәтерлисезме — төне нинди иде? Һавасы шундый саф иде, татлы хуш исләр аңкып тора иде. Зәңгәр күктә йолдызлар җем-җем итә иде. Һай, шул чагында, ханым, бик аз гына бер вакытка мин сезнең белән икәүдән икәү генә калу бәхетенә ирештем. Ул чагында сез миңа барысын да: ялгызлыгыгыз турында да, ханыгызның газап чигүе турында да сөйләргә әзер идегез. Сез минем беләгемә тотындыгыз... менә шушы беләгемә. Иелә төшкән чакта мин сезнең искиткеч чәчләрегезнең битемә орынуын тойдым, һәм чәчләрегез орынган саен баштанаяк минем бөтен тәнем калтырана башлый иде. Королева, һай, королевам! Шундый мизгелдә нинди оҗмах бәхетләре, нинди җәннәт рәхәтләре барлыгын белсәгез икән!.. Шул мизгел өчен, шундый төн өчен мин бөтен биләмәләрем, байлыгым, данымны, гомеремнең калган көннәрен дә бирергә әзермен. Чөнки, анттыр, ул төнне, ханым, ул төнне сез яраттыгыз бит мине!..

— Милорд, ихтимал... шулайдыр, андагы җирләрнең яме,

ул гаҗәеп кичнең матурлыгы, сезнең күз карашыгызның тәэсире, хатын-кызны харап итү өчен бергә килеп кушыла торган әнә шундый исәпсез күп сәбәпләр шул тәкъдир кичендә минем тирәмә тупланган булгандыр. Әмма сез күрдегез бит, милорд,— королева булуым бирешә башлаган хатынга ярдәмгә килде: сез җөрьәт итеп беренче сүзне әйтүгә үк, беренче тыйнаксызлыгыгызга мин каршы җавап бирергә тиеш булгач ук асравымны чакырып китердем.

— Әйе, әйе, анысы хак. Минекеннән башка икенче бер мәхәббәт андый сынауларга түзә алмас иде. Әмма минем мәхәббәтем, ул сынауларны узып, тагы да катырак дөрли башлады, мәңгелеккә йөрәк түремә кереп урнашты. Сез Парижга кайтып миннән котылдым дип уйладыгыз, галиҗәнап хуҗам сакларга кушкан хәзинәләрне ташлап китәргә мине җөрьәт итмәс дип уйладыгыз. Минем ул хәзинәләргә дә, бөтен җир шарындагы корольләргә дә исем китми! Минем кире әйләнеп килгәнемә атна да юк әле, ханым. Бу юлы сезгә мине шелтәләрлек сәбәп юк. Сезне бер генә мизгел күреп калу өчен мин королемнең шәфкатен югалту куркынычына бардым, гомеремне кыл өстенә куйдым, мин хәтта сезнең кулыгызга да орынмадым, һәм сез минем тәүбә итүемне, карусызлыгымны күреп, мине гафу иттегез.

— Анысы шулай, әмма ялачылар минем бернинди гаебем булмаган әнә шул акылсызлыклардан файдаландылар — минем гаепсез икәнемне сез үзегез дә беләсез, милорд. Кардинал җәнапларының коткысы нәтиҗәсендә король бик яман тузгынды. Де Верне ханымны сарайдан кудылар, Пютанжны Франциядән сөрделәр, де Шеврез ханым каһәргә эләкте. Сез Франциягә илче булып килергә теләгәч, король үзе — исегезгә төшерегез, милорд,— король үзе моңа каршы төште.

— Әйе, шулай. Короленең баш тартканы өчен Францияне сугыш көтәчәк. Мин сезне күрү мөмкинлегеннән мәхрүммен, ханым,— ярый, мин көн саен сезгә үзем турында ишеттереп торырга тырышырмын. Ре атавына булган экспедициянең һәм минем Ларошель протестантлары белән союз төзергә ниятләвемнең максаты ни икәнен беләсезме? Сезне күрү ләззәте ул. Мин корал белән килеп Парижны алырыма өметләнмим, анысын беләм. Әмма бу сугыштан соң солых булачак, ә солых төзү өчен ике арада сөйләшү кирәк, сөйләшүне исә миңа тапшырачаклар. Ул чагында инде мине кабул итми калмаячаклар. Шуннан соң мин Парижга киләчәкмен, сезне бер генә мизгел ара булса да күрү бәхетенә ирешәчәкмен. Дөрес анысы, шушы бәхет өчен меңләгән кеше гомерләрен бирәчәкләр. Әмма минем аңа исем китми,— миңа фәкать сезне күрергә генә булсын! Бәлки, бу — акылсызлыктыр, бер саташудыр, әмма шулай да әйтегез әле: кайсы хатынның шулкадәр ялкынланып сөюче кешесе булган? Кайсы королеваның шулкадәр тугрылыклы ялчысы булган?

— Милорд, милорд, сез үзегезне аклар өчен үзегезгә үк кара яга торган дәлилләр китерәсез. Милорд, сез әйткән мәхәббәт дәлилләре — җинаять чигендәге бер нәрсә бит.

— Сез, ханым, мине сөймәгәнгә генә шулай тоела ул. Әгәр сез мине сөйсәгез, ул дәлилләр сезгә бөтенләй башкача булып тоелыр иде. Әмма сез мине сөйсәгез... Әгәр сез мине сөйсәгез, бәхетем чигеннән ташып, мин акылымнан шашар идем. Әйе, менә сез әле генә телгә алган де Шеврез ханым ул кадәр шәфкатьсез булмаган: Голланд аны сөйгән, ханым аның мәхәббәтенә мәхәббәте белән җавап кайтарган.

— Де Шеврез ханым королева түгел шул,— дип пышылдады Анна Австрияле, шундый көчле тойгыга каршы тора алмыйча.

— Димәк, сез, ханым, королева булмасагыз, мине сөяр идегез? Әйеме? Сөяр идегезме? Сезне олуг дәрәҗәгез генә шулай каты торырга мәҗбүр итә дип уйларга хакым бармы? Әгәр сез де Шеврез ханым булсагыз, бичара Бекингэм мәхәббәт өмет итә алыр иде дип уйларга хакым бармы?.. Мондый татлы сүзләрегез өчен рәхмәт сезгә, гүзәл королевам, мең рәхмәт!

— Милорд, милорд, сез дөрес аңламадыгыз, минем сүзләремә дөрес мәгънә бирмәдегез. Мин алай дип әйтергә...

— Әйтмәгез, әйтмәгез! — диде герцог.— Әгәр бәхетем мине ялгыштырган икән, аны төзәтеп ул кадәр рәхимсез булмагыз. Үзегез әйттегез бит, мине алдап тозакка төшергәннәр. Ихтимал, мин исән дә калмам... Гаҗәп бер хәл: соңгы вакытта мин әҗәлем якынлашкан кебек хис кылам үземне...— Шулай дигәч, герцог хәсрәт кичергән бер төс белән, шул ук вакытта сокландыгыч бер сөйкемлелек белән елмаеп куйды.

— Яраббым! — диде Анна һәм аның шушылай аһ оруы герцогка булган тойгысының үзен тотышындагыга караганда никадәр көчле икәнлеген сүзсез дә белгертте.

— Мин моны, ханым, сезне куркытыр өчен әйтмәдем. Һич юк! Минем ул сүзем көлке булып кына тоелырлык; хыялның алай шаяруы, ихластыр, мине тамчы да борчымый. Әмма әле яңа гына сез әйткән сүз, миңа сез бирә язган өмет алдан ук барысын да, хәтта минем үлемемне дә йолдылар.

— Хәзер инде мин дә яшерми әйтим, герцог,— диде Анна,— минем дә күңелем нииндидер шом сизә, әллә нинди төшләр күрәм. Төшемдә мин сезне күрдем: сез яраланып, канга батып җирдә ятасыз, имеш...

— Сул янтыгым яраланган, пычак белән кадаганнар идеме? — диде герцог аны сүзеннән бүлдереп.

— Әйе, нәкъ шулай, милорд: сул янтыгыгыз, пычак ярасы. Минем андый төш күрүемне кем сөйләве мөмкин сезгә? Мин бит аны бер ходаема гына ачтым, гыйбадәт кылганда гына.

— Шул бик җиткән, ханым. Сез мине сөясез — шул җиткән.

— Мин сезне сөям? Мин?

— Әйе, сез. Әгәр сез мине яратмасагыз, ходай сезгә дә, миңа да бер үк төш күрдерер идемени? Әгәр безнең йөрәкләре-

без гомерләребезне бергә бәйләмәсә, күңелләребезгә бер үк шомлы тойгылар керер идеме! Сез мине сөясез, королевам. Сез мине кызганып еларсызмы?

— Яраббым! Яраббым! — диде Анна Австрияле.— Түзәр хәлләрем калмады. Герцог, алла хакы өчен дип гозерләп сорыйм: китегез, калдырыгыз мине! Мин сезне яратамдырмы, юкмы — белмим, әмма антларымны бозмаячагымны бик яхшы беләм. Ичмасам, кызганыгыз мине, китегез! Әгәр дә сезне Франциядә яраласалар, әгәр сез Франциядә үлеп калсагыз, әгәр күңелемдә сезнең үлемегезгә мине сөюегез сәбәп булды дигән уй туса, мин моңа түзә алмаячакмын, акылымнан язачакмын. Зинһар, китегез, алла хакы өчен, китегез!

— О, нинди гүзәл сез хәзер! Шашып яратам мин сезне! — диде Бекингэм.

— Китегез! Китегез! Зинһар өчен! Соңрак тагын килерсез. Биргә илче булып, министр булып килерсез, сезне сакларга әзер торган сакчыларыгыз белән, сезне сакларга тиешле хезмәтчеләрегез белән килерсез. Ул чагында инде мин сезнең исәнлегегез өчен дер калтырап тормам, сезне күрүемә бик шат булырмын.

— Сезнең бу сүзләрегез чынмы?

— Әйе...

— Ул чагында... ул чагында мине кичерүегезнең билгесе итеп миңа берәр нәрсә бирегез, минем боларны төшемдә генә пшетмәгәнлегемне раслый торган берәр әйберегезне бирегез. Үзегез тагып якн киеп йөри торган һәм мин дә тагып я киеп йөрерлек берәр әйберегезне... йөзек, чылбыр тасма...

— Шушы теләгегезне үтәсәм, сез китәсезме, китәсезме?

— Әйе.

— Хәзер үкме?

— Әйе.

— Франциядән китәсез? Англиягә кайтасызмы?

— Әйе, ант итеп әйтәм.

— Алайса, аз гына сабыр итегез.

Анна Австрияле үз бүлмәсенә чыгып китте дә шундук диярлек әйләнеп тә керде. Аның үз монограммасын язып, асыл агачтан эшләнгән тартма тоткан иде ул кулына.

— Мәгез, милорд,— диде Анна,— мәгез, минем төсем итеп саклагыз.

Герцог Бекингэм тартманы алды да яңадан Аннаның аягына егылды.

— Китәргә сүз бирдегез бит миңа,— диде королева.

— Сүз бирдем һәм сүземдә торачакмын. Кулыгызны бирегез, ханым, кулыгызны бирегез, аннары мин китәм.

Королева Анна, күзен йомып, икенче кулы белән Эстефаниягә тотынып, герцогка кулын сузды, чөнки хәле китә башлавын сизгән иде.

Бекингэм кайнарланып шул гүзәл кулга иреннәрен тидерде,

— Дөньяның астын өскә китерергә туры килсә дә, тагын бер ярты елдан мин сезне яңадан күрәчәкмен,— дип сөйләнде ул аягына басканда.

Һәм, әйткән вәгъдәсендә торып, бүлмәдән йөгереп чыгып китте.

Коридорда ул Бонасье ханымны тапты. Ханым, кергәндәге шикелле үк, зур саклык һәм ышаныч белән аны Луврдан чыгарып җибәрде.

## XIII

## БОНАСЬЕ ӘФӘНДЕ

Укучы сизгәндер инде: шушы вакыйгаларда, бик авыр хәлгә эләгүенә карамастан, беркемне дә кызыксындырмаган бер кеше бар иде. Ул кеше рыцарь каһарманлыклары һәм мәхәббәт мажараларына бик бай бу заманда үзара керешеп чуалып бетә торган политика һәм мәхәббәт интригаларының мөхтәрәм бер корбаны Бонасье әфәнде иде.

Бәхеткә каршы — укучы хәтерлидерме, юктырмы — без аны күздән югалтмаска дип сүз биргән идек.

Бонасье әфәндене кулга алучы шымчылар аны туп-туры Бастилиягә алып киттеләр дә, дер калтыраган хәлендә, мушкетларын корып матайшкан бер взвод солдат янышнан уздырдылар.

Аннары, яртылаш җиргә иңгән озын бер коридорга килеп кергәч, озата килүчеләр аңа бик каты мөгамәлә күрсәтеп, әллә нинди тупас сүзләр әйтеп сүгәргә керештеләр. Бу кешенең дворян затыннан түгеллеген белгәч, шымчылар аңа урамдагы бер хәерче сыман итеп кенә карадылар.

Бер ярты сәгатьтән соң писарь килеп, аны газаптан коткарса да, борчудан арындырмады: аны сорау ала торган бүлмәгә илтергә кушты. Гадәттә тоткыннардан сорауны үз камераларында ала торганнар иде, ләкин Бонасье әфәндедән уңайсызланып торуны кирәк санамадылар. Ике конвойчы, бичара галантерейчыны эләктереп алып, ишегалдыннан уздырдылар, өч сакчы басып торган бер коридорга керттеләр дә ниндидер бер ишекне ачып, гөмбәз сыман түшәмле бүлмә эченә этеп кертеп җибәрделәр. Бу бүлмәдә бер өстәл белән бер урындык һәм комиссар бар. Комиссар өстәл янында урындыкта нидер язып утыра иде.

Конвойчылар тоткынны өстәл катына китерделәр дә, комиссар ым кагуга, аның сүзе ишетелмәслек арага ераграк китеп бастылар.

Моңарчы кәгазьләре өстенә башын иеп утырган комиссар, каршысында кем басып торганлыгын тикшергән кебек, кинәт күтәрелеп карады. Комиссарның кыяфәте бик ягымсыз, төмсә

иде — очлы борынлы, сары янаклы иде ул, янак сөякләре калкып тора, күзләре кечкенә, тере, үткен карашлы. Кыяфәтендә бер үк вакытта сусарны да, төлкене дә хәтерләтә торган бер чалым бар иде. Хәрәкәтчән озын муены судьялар кия торган кара мантиясенең якасы эченнән сузаеп чыгып тора, шуңа күрә башы таш кабыгы эченнән чыккан ташбака башы сыман селкенә иде.

Комиссар иң элек Бонасье әфәнденең исем, фамилиясен, нинди эш белән шөгыльләнүен һәм кайда торуын сорады.

Җавапка тартылучы үзенең исеме Жак-Мишель Бонасье икәнлеген, үзенә илле бер яшь булуын, элек галантерея кибете тотканлыгын, хәзер инде сәүдә эшен ташлаган булуын, Каберчеләр урамында унберенче йортта торуын әйтте.

Шуннан соң комиссар, сорау алуын дәвам иттерәсе урында, политикага килеп кысылган бу кечкенә кешегә нинди куркыныч килгәнлеге турында озын гына нотык сөйләде. Аннары кардинал хәзрәтләренең кодрәте һәм көче турында сөйләргә кереште: имеш, моңарчы әле андый министр булмаган; имеш, узгандагы бөтен министрлардан бик күп өстен икән ул, киләчәктәге министрларга гүзәл үрнәк булырлык икән, аның эшенә һәм хакимлегенә комачаулык итүчеләр берсе дә җәзасыз калмый икән.

Нотыгының шул өлеше беткәч, комиссар, карчыга күзедәй үткен күзләре белән бичара Бонасьега батырып карап, аңа үзенең хәле турында уйланырга кушты.

Вак товар кибете хуҗасының уйлары әллә ни катлаулы булмады: ул фәкать де Ла Порт әфәнде үзе исем атасы булган кызга аны өйләндерергә ниятләгән көнне, бигрәк тә бу кызның королеваның кастеляншасы итеп алынган сәгатьне генә каргады.

Бонасье әфәнденең холык-характер нигезе коточкыч эгоизмнан һәм бинаһая куркаклык белән аралашкан искиткеч бер саранлыктан гыйбарәт иде. Аның яшь хатынын яратуы икенчел дәрәҗәдәге бер тойгы гына, шуңа күрә бу тойгысы тумышыннан бирелгән әлеге сыйфатлары белән ярыша алырлык түгел иде.

Бонасье үзенә кушылганны бик җитди итеп уйлады да, каушамыйча, сабыр гына, сүзгә кереште:

— Комиссар әфәнде, ихластыр, безне идарә итүче тиңдәшсез галиҗәнапның барлык яхшы сыйфатларын мин башкаларга караганда да күбрәк беләм һәм күбрәк тәкъдир итәм.

— Шулай укмыни? — диде комиссар ышанмыйча.— Әгәр чыннан да шулай икән, ул чагында Бастилиягә ничек килеп эләктегез соң сез?

— Бирегә мин ничек, дөресрәге — ни өчен килеп эләккәнмен — менә анысын мин сезгә берничек тә әйтеп бирә алмыйм, чөнки мин аны үзем дә белмим. Мөгаен, кардинал хәзрәтләренә ярамаслык эш кылганым өчен түгелдер.

— Сезне дәүләткә хыянәт итүдә гаеплиләр икән, димәк, сез ниндидер җинаять эшләгән булырга тиешсез.

— Дәүләткә хыянәт иткәнмен? — дип коты чыгып кычкырып куйды Бонасье.— Дәүләткә хыянәт иткәнменме?.. Һугенотлар белән испаннарны дошман күргән бичара бер галантерейчыны ничек итеп дәүләт хыянәтчесе дип гаепләргә мөмкин? Үзегез уйлап карагыз, комиссар әфәнде. Бу бит бөтенләй акылга сыймаслык хәл!

— Бонасье әфәнде, — диде комиссар, кечкенә генә күзләре белән гаепләнүченең күңел түрендә ниләр барлыгын күреп торган сыман итеп карады.— Бонасье әфәнде, сезнең хатыныгыз бармы?

— Әйе, әфәндем, — дип калтырана-калтырана җавап кайтарды галантерейчы. менә хәзер шушы җирдә инде эшнең катлауланып китәсен тойды.— Минем... минем хатыным бар иде.

— Ничек ул — бар иде? Булгач, кая куйдыгыз соң сез аны?

— Хатынымны урладылар, әфәндем.

— Урладылар? — дип кайтарып сорады комиссар.— Менә сиңа кирәк булса!

«Менә сиңа кирәк булса!» дигән сүздән Бонасье эшнең тагы да чуала башлавын төшенде.

— Хатыныгызны урладылар дисез, алайса. Ә кем урлаганын беләсезме соң? — диде комиссар.

— Беләм шикелле.

— Кем?

— Исегезгә алыгыз, комиссар әфәнде, мин тәгаен дип бернәрсә дә әйтмим. Мин фәкать шикләнәм генә.

— Кемнән шикләнәсез? Я, турысын әйтегез.

Бонасье әфәнде аптырашта калды: бер нәрсә дә әйтмәскәме, әллә яшермичә бөтенесен сөйләп бирергәме? Әгәр ул бөтенесен инкарь итеп барса, бик күп белә икән бу, шуңа күрә дөресен сөйләп бирергә курка дип уйлаулары бар. Дөресен сөйләсә, үзенең ихлас булуын күрсәтәчәк. Шуңа күрә ул барысын да сөйләп бирергә булды.

— Мин бер ирдән шикләнәм — озын гына буйлы, кара чәчле, кара тутлы, бай вельможага охшаган ире генә кыяфәтле бер кеше. Мин хатынымны Лувр Капкасы төбендә көтеп алып өйгә кайтарган чагымда ул беренче тапкыр безнең арттан иярәп килде кебек тоелган иде миңа.

Комиссар беркадәр тынычсызлана башлаган сыман булды.

— Исеме ничек аның? — дип сорады.

— Ай, исемен белмим шул. Мин аны очратсам, мең кеше арасыннан да таныр идем, валлаһи.

Комиссар кашын җыерды.

— Мең кеше арасыннан да таныр идем дисезме? — дип кайтарып сорады.

— Мин ни димәкче идем...— дип мыгырданды Бонасье, җавабының уңышлы булмаганлыгын сизеп.— Мин ни димәкче идем...

— Сез, танып идем, дип әйттегез,— диде комиссар.— Яхшы. Бүгенгә шул җиткән. Без бу сүзне яңадан дәвам иттергәнче, сезнең хатыныгызны кем урлаганлыгын белүегез хакында кайбер кешеләргә белгертеп куярга кирәк.

— Аны тәгаен беләм дип әйтмәдем бит мин сезгә! — дип, тәмам хафага төште Бонасье.— Мин моның нәкъ киресен әйттем...

— Тоткынны алып китегез! — дип боерды комиссар ике стражникка.

— Аны кая илтергә боерасыз? — дип сорады писарь.

— Камерага.

— Кайсы камерага?

— Ах алла, теләсә кайсына! Тазарак бикләнә торганы гына булсын,— диде комиссар салкын бер тавыш белән. Шул салкынлык бичара Бонасьеның йөрәгенә курку булып ябышты.

«Ай аллам, ай аллам! Харап кына ла булдым! — дип уйланды ул күңеленнән.— Хатыным берәр төрле коточкыч җинаять кылгандыр, күрәсең. Мине аның белән бергә эш иткән дип уйлыйлардыр, аның белән бергә җәзалап үтерәчәкләр мине. Хатыным барысын сөйләп биргән дә бу эшкә мине дә катнаштырдым дигәндер. Хатын-кыз көчсез зат шул!.. Беренче туры килгән камерага, ди! Әлбәттә шулай! Төн кыска... иртәгә инде — әҗәл арбасы, дар агачы... Ай аллам, ай аллам! Коткар бәндәнне!»

Бонасье әфәндене мескенләнеп шыңшуына тамчы да әһәмият итмәстән (хәер, андый шыңшуларга алар күптән нык ялкып беткәннәрдер инде), сакчылар тоткынны ике ягыннан култыкладылар да камерага алып киттеләр. Комиссар тиз-тиз генә ниндидер хат язарга кереште. Писарь, хатның язылып беткәнен көтеп, аның янында басып калды.

Бонасье бу төнне күзен дә йоммады — камерасы бик җайсыз булганга түгел, коточкыч бер курку тойгысы йокы бирмәде аңа. Шылт иткән тавышка да сискәнә-сискәнә, төн буе эскәмиядә утырып чыкты. Иртән тәрәзә рәшәткәләре аша камерага эченә беренче нурлар төшкәч, кояшның үзенә дә кайгы чырае кергән сыман тоелды аңа.

Кинәт ишектәге бикнең ачыла башлаганы ишетелде, һәм Бонасье куркуыннан хәтта атылып ук торды. Ул үзен эшафотка алып китәргә килделәр дип уйлады. Шуна күрә ишектән җәлад урынына кичәге комиссар белән писарь килеп кергәч, ул аларның муеннарына барып асылынырдай булды.

— Сезнең эшегез, кадерлем, кичәге көннән башлап бик чуалып китте,— диде комиссар.— Мин сезгә дөресен сөйләп бирергә киңәш итәм. Ихлас күңелдән тәүбә итеп кенә сез кардиналның рәхим-шәфкатенә исәп тота аласыз.

— Мин бит барысын да сөйләп бирергә әзер! — диде Бонасье.— Һич югы, белгәннәремне сөйләп бирә алам. Рәхим итегез, сорагыз миннән.

— Иң элек шул: хатыныгыз кайда хәзер?

— Мин бит инде сезгә әйттем: аны урладылар, дидем.

— Анысы шулай, ә менә кичә көндезге сәгать биштән соң сезнең ярдәмегез белән качкан бит ул.

— Хатыным качкан? — диде Бонасье гаҗәпкә калып.— Ай, бичара! Әфәндем, әгәр ул качкан булса, ул эштә минем бер гаебем дә юк бит, анттыр!

— Ни өчен сез көндез фатирчыгыз д'Артаньян янына кердегез? Аның белән ни турындадыр озак кына киңәшеп утыргансыз.

— Әйе, анысы хак, комиссар әфәнде, монысын танмыйм, бу эшемнең хата булганлыгын икърар итәм. Д'Артаньян әфәнде янына чыннан да кергән идем.

— Нинди максат белән кергән идегез?

— Хатынымны табып бирмәссезме дигән үтенеч белән. Мин хатынымны кире кайтарып алырга хакым бар дип уйлаган идем. Күрәсең, ялгышканмын. Моның өчен мине гафу итүегезне бик үтенеп сорыйм.

— Д'Артаньян әфәнде ни дип җавап бирде соң сезгә?

— Д'Артаньян әфәнде миңа булышырга вәгъдә итте. Ләкин озакламый мин аның үземә хыянәт иткәнлегенә ышандым.

— Сез судны ялгыш юлга кертеп җибәрергә маташасыз! Д'Артаньян сезнең белән бер сүздә булган, шуның нәтиҗәсендә ул сезнең хатыныгызны кулга алган полицейскийларны кыйнап чыгарган да хатыныгызны эзәрлекләүдән коткарып калган.

— Д'Артаньян әфәнде минем хатынымны урлап киткәнмени? Ни сөйлисез сез?

— Бәхеткә каршы, д'Артаньян әфәнде үзе безнең кулда. Сезне аның белән күзгә-күз очраштырачакбыз.

— Ярый, монысына мин бик шатмын! — диде Бонасье әфәнде.— Һич югы берәр таныш кеше күрәсе иде.

— Д'Артаньян әфәндене кертегез! — дип боерды комиссар сакчыларга.

Сакчылар камерага Атосны китереп керттеләр.

— Д'Артаньян әфәнде, сезнең белән шушы әфәнде арасында ниләр булганлыгын сөйләп бирегез әле,— диде комиссар Атоска.

— Бөтенләй д'Артаньян әфәнде түгел ич бу! — дип кычкырып әйтеп куйды Бонасье.

— Ничек д'Артаньян әфәнде түгел? — дип, комиссар да үз нәүбәтендә кычкырып әйтте.

— Әлбәттә, ул түгел! — диде Бонасье.

— Алайса бу әфәндегең исеме ничек соң? — дип сорады комиссар.

— Анысын мин сезгә әйтә алмыйм: мин бу кеше белән таныш түгелмен.

— Сез аның белән таныш түгел дисез?

— Әйе.

— Сезнең аны бер дә күргәнегез юк идеме?

— Күргәнем бар, ләкин исемен белмим.

— Исемегез ничек? — дип сорады комиссар.

— Атос, — диде мушкетер.

— Кеше исеме түгел ич бу, ниндидер тау исеме! — диде бичара комиссар, аптырашта калып.

— Минем исемем шундый, — диде Атос сабыр гына.

— Сез бит исемегезне д'Артаньян дип әйткәнсез?

— Мин шулай дип әйткәнменме?

— Әйе, сез.

— Гафу итәсез! Миннән: «Сез д'Артаньян әфәнде буласызмы?» — дип сорагач, мин әйттем: «Шулай дип уйлыйсызмы?» — дидем. Стражниклар, без анысын тәгаен беләбез, дип кычкырына ук башладылар. Мин инде бәхәскә кереп тормадым. Аннары, минем бит ялгышуым да ихтимал.

— Әфәндем, сез судны мыскыл итәсез.

— Тамчы да мыскыл итмим, — диде Атос сабыр гына.

— Д'Артаньян әфәнде сез!

— Менә бит, сез дә яңадан шул ук сүзне кабатлыйсыз.

— Комиссар әфәнде, — дип кычкырып эндәште Бонасье. — Ихластыр, монда бернинди шик булуы мөмкин түгел! Д'Артаньян әфәнде ул — минем фатирчым, шулай булгач, ул миңа фатир хакы түләмәсә дә, ягъни түләмәгәнгә күрә дә мин инде белергә тиешмен. Д'Артаньян әфәнде унтугыз-егерме яшьләрендәге бер егет, яше шуннан артык түгел, ә бу әфәндегә ким дигәндә утыз яшь. Д'Артаньян әфәнде Дезэссар әфәнденең гвардиячеләр ротасында хезмәт итә, ә бу әфәнде — де Тревиль әфәнде ротасының мушкетеры. Сез аның киеменә күз салыгыз, комиссар әфәнде, киеменә күз салыгыз!

— Дөрес шул! Дөрес бу, шайтан алгыры! — дип мыгырданды комиссар.

Шул минутта ишек ачылып китеп, Бастилиянең бер надзирателе камерага хәбәр йөртүчене кертте, анысы комиссарга ниндидер хат тапшырды.

— Ах, җүнсез хатын! — дип тиргәнеп куйды комиссар.

— Ничек, ничек? Нәрсә дидегез? Кем турында әйтәсез сез? Минем хатын турында түгелдер, шаять?

— Әйе, нәкъ аның турында. Әйтәсе дә юк, эшләрегез бик шәп сезнең!

— Нәрсә булган, ни булган? — диде галантерейчы тәмам хафага төшеп. — Аңлатып бирегезче, комиссар әфәнде: мин төрмәдә утырган чакта хатыным кылган эшләрдән ничек итеп минем эшләр начарланып икән?

— Чөнки хатыныгыз кыла торган эшләр барысы да сезнең

бергәләп корган планыгызның дәвамы гына! Бик яман планыгызның дәвамы!

— Анттыр әгәр, комиссар әфәнде, сез бик каты хаталанасыз: хатынымның иләр кылырга ниятләве хакында мин берни белмим, аның кылган эшләренә минем бернинди катнашым юк, әгәр дә ул ахмаклыклар эшләп ташлаган икән, мин аннан баш тартам, ваз кичәм, каргыйм мин аны!

— Менә нәрсә, комиссар әфәнде,— дип кинәт Атос сүзгә кушылды.— Әгәр мин сезгә бүтән кирәк булмасам, мине берәр җиргә илтеп ябарга кушсагыз иде. Сезнең бу Бонасье әфәндегездән мин туеп гарык булдым.

— Тоткыннарны камераларына илтегез,— дип боерды комиссар, Атос белән Бонасьеның якесенә таба берьюлы ымлап,— әйтегез: ныграк сакласыннар аларны.

— Әгәр сезнең д'Артаньян әфәндегә дәгъвагыз бар икән, мин аны ни дәрәҗәдә алмаштыра алуымны һич аңламыйм,— диде Атос, гадәтенчә сабыр гына.

— Ничек кушылган — шулай эшләгез! Тышкы дөнья белән бернинди бәйләныш юк! Ишеттегезме? — дип кычкырды комиссар.

Атос җилкәсен генә сикертте дә сакчылар артыннан иярде, ә Бонасье юл буе шулкадәр елады, ыңгырашты, аһ-уһ килде — хәтта юлбарысның да күңелен нечкәртер иде бу хәл.

Галантерейчыны төн куңган камерасына илтеп яптылар һәм көн буена шунда калдырдылар. Бонасье, чын галантерейчы шикелле, көн буе елап-сыктап утырды: үз сүзе белән әйтсәк, аңарда гаскәри рух дигәннең әсәре дә юк иде шул.

Кичке сәгать тугызлар тирәсендә, йокларга җыена башлагач, ул коридорда аяк тавышлары ишетте. Тавыш аның камерасына якынлашты, һәм, ишек ачылып, камерага сакчы солдатлар килеп керде.

— Минем белән барыгыз,— диде аңа солдатлар белән бергә килеп кергән полиция чиновнигы.

— Сезнең белән барырга? — диде Бонасье, гаҗәпләнеп.— Бу вакыт җиткәч сезнең белән барырга? Кая барабыз, йа раббым?!

— Кая китерергә боерган булсалар — шунда барабыз.

— Бу бит җавап түгел!

— Без сезгә шуннан башканы әйтә алмыйбыз.

— Ай аллам, ай аллам! Бу юлы беттем инде! — дип пышылдады бичара Бонасье.

Һәм ул, тәмам миңгерәүләнгән-түнгән бер хәлдә, бернинди каршылык күрсәтмичә, сакчылар артыннан иярде.

Аны бер тәпкыр булган теге коридор аша уздырдылар, аннары ишегалды аша үттеләр, икенче бер бинаны аркылы чыктылар, һәм, ниһаять, төп йортның капкасына җиттеләр. Капка төбендә аларны карета көтеп тора, каретаны исә дүрт атлы сакчы чолгап алган иде. Бонасьены каретага кертеп

утырттылар, полиция чиновнигы үзе дә аның янына кереп утырды, ишекне ачкыч белән бикләп алгач, алар тәгәрмәчле бер төрмәгә ябылган кебек булдылар.

Карета, матәм арбасы шикелле, әкрен генә урыныннан кузгалып китте. Тәрәзәдәге рәшәткә аша тоткынга йортлар белән урам ташлары гына күренә иде. Ләкин Бонасье кебек гомере буе Парижда яшәгән кеше һәр урамны чаттагы баганаларына, вывеска һәм фонарьларга карап та таный иде. Изге Павел чиркәве янына җиткәндә (шул чиркәү янында Бастилиянең үлемгә хөкем ителгән тоткыннарын җәзалап үтергәннәр иде), Бонасье һушыннан яза башлап, ике тапкыр чукынып куйды. Каретаны ул шунда туктар дип уйлаган иде. Ләкин чиркәүне дә узып киттеләр.

Бераздан аның тагын коты ботына төште. Алар дәүләткә каршы җинаять кылучыларны күмә торган изге Яков зираты яныннан уза башладылар. Тик ул бер генә нәрсәне уйлап беркадәр тынычлана төште: гадәттә андый җинаятьчеләрне зиратка күмгәнче башларын кисә торганнар иде, ә аның үз башы урынында иде әле. Әмма каретаның Грев мәйданына борылуын, шәһәр ратушасының очлы түбәсен һәм каретаның зур капкадан кереп китүен күргәч, ул «беттем!» дип уйлады һәм полиция чиновнигына соңгы васыятьләрен әйтмәкче булды. Чиновник аны тыңлаудан баш тарткач, Бонасье шундый кызганыч тавыш белән шыңшып кычкыра башлады — чиновник аны, туктамасаң, авызына чүпрәк тыгам, дип куркытырга мәҗбүр булды.

Чиновникның шул сүзеннән соң Бонасье бераз тынычланган кебек булды. Әгәр аны Грев мәйданында җәзаларга җыенсалар, авызына чүпрәк тутырып маташмаслар да иде: җәзалый торган тешкә килеп җитә яздылар бит инде. Чыннан да, карета, туктамастан, мәйдан аша үтеп китте. Мондый шомлы урыннардан тагын Трауар Тәресе генә бар иде. Карета нсә нәкъ әнә шунда таба борылды.

Бу юлы инде бернинди шик калмады: Трауар Тәресе мәйданында түбән катлау җинаятьчеләрен җәзалап үтерәләр иде. Бонасье әфәнде юкка гына үзен изге Павел яисә Грев мәйданына лаек дип санап юанган булган икән. Аның бу сәяхәте һәм гомере Трауар Тәресе янында бетәчәк. Ул каргышлы төре әле күренмәсә дә, Бонасье әфәнде аның үзенә таба якыная барганын тәне белән диярлек тоеп килә иде инде. Шул хәтәр урыннан егерме адым чамасында ул халык шаулашкан тавыш ишетте. Карета туктады. Юл буе коты чыгып килгән бичара Бонасье бу кадәресен инде күтәрә алмады. Ул җан биргәндәге сыман зәгыйфь бер тавыш белән «аһ!» диде дә һушыннан язды.

## XIV

## МЕҢГТА ОЧРАГАН ЯТ КЕШЕ

Бу халык мәйданга кеше асуларын күтеп җыелмаган, бәлки асылган кешене карарга килгән иде.

Шуңа күрә карета аз гына туктап торды да, кузгалып китеп, халык арасыннан узды, Сент-Оноре урамы башыннан үтеп, Яхшы Балалар урамына борылгач, түбәнәгрәк бер подъезд янына килеп туктады.

Карета ишеге ачылуга, полицейский ярдәмендә каретадан чыккан Бонасьены ике гвардияче кочакларына күтәреп җиргә төшерделәр. Аннары аны озын бер вестибюльгә төртеп керттеләр дә, ниндидер баскычтан менгезеп, алгы бүлмәдә калдырдылар.

Ул нишләргә тиеш булса, шул хәрәкәтләрнең барысын үз алдына, ихтыярыннан тыш эшли иде.

Йөрүе дә төштәге кебек кенә, тирә-юньдәге әйберләрне томан аша гына күргән сыман. Колагына ниндидер тавышлар ишетелсә дә, аларның нинди тавыш икәнен аермый иде. Әгәр шушы минутта аны җәзалап үтерергә керешсәләр, ул үз җанын саклап селкенмәс-кыймылдамас та, шәфкать сорап «ыһ» та димәс иде.

Әнә шул хәлендә ул банкеткада, сакчылар утыртып калдырган төштә, стенага сөялеп, кулларын салындырган килеш утыра бирде.

Шулай да, әкренләп як-ягына карана торгач, үзенә әҗәл куркынычы китерердәй нәрсәләр күрмәгәч,— стеналар йомшак күн белән тышланган, кызыл төстәге авыр ефәк чаршаулар алтын баулар белән күтәртебрәк куелган, ул утырган банкетка да ярыйсы ук йомшак, җайлы иде,— шулай итеп, шикле нәрсә күрмәгәч, ул куркуы юкка икәнен аңгарып алды һәм башын уңга-сулга бора, күтәрә-төшерә башлады.

Аның мондый хәрәкәтләренә беркем дә каршылык кылмагач, ул беркадәр батырая да төште, башта бер аягын, аннары икенчесен бөгәргә йөрәге җитте. Ахырында инде ул куллары белән диван утыргычына таянды да, күтәрелә төшеп, аягына басты.

Шул минутта мәһабәт кенә кыяфәтле бер офицер чаршауның бер кырыен күтәрде, үзе һаман күрше бүлмәдәге берәү белән сөйләшүендә дәвам итте. Шуннан соң гына тоткынга борылып карады да:

— Бонасье сез буласызмы? —дип сорады.

— Әйе, офицер әфәнде, мин булам, баш өсте,— дип мыгырданды галантерейчы, коты ботына төшеп.

— Керегез,— диде офицер.

Үзе, тоткынга юл биреп, бер читкәрәк авышты. Бонасье,

бернинди каршылыксыз буйсынып, бүлмәгә керде. Монда анын кергәнен көтеп торалар иде инде, күрәсең.

Кергән җире иркен генә бер кабинет булып, стеналарына төрле кораллар элеп куелган иде; тыштагы бернинди тавыш та ишетелми монда. Әле сентябрь азаклары гына булса да, каминга ут ягып җибәргәннәр. Бүлмәнең урта бер җирен дүрт почмаклы зур гына өстәл биләп тора, өстәл өсте китап-кәгазь белән тулган, шулар өстенә Ларошель каласының зур гына картасы җәеп салынган иде.

Камин янында уртача буйлы, тәкәббер-горур кыяфәтле, үткен карашлы һәм киң генә маңгайлы бер кеше басып тора иде. Анын чөй шикелле очлы сакалы чандыр йөзен тагы да озынчарак итеп күрсәтә, сакалыннан өстәрәк як-якка бөтерке мыегы тырпаеп тора. Бу кешенең яше утыз алты-утыз җиделәрдән артык булмаса да, чәче белән сакалына инде чал керә башлаган иде. Билендә кылычы булмаса да, үзе хәрби кешегә охшаган, юка гына булып күн итекләренә кунган тузан исә анын бу көнне атка атланып юл йөреп кайтканлыгын әйтеп тора иде.

Әлеге кеше Арман-Жан Дюплесси, кардинал де Ришелье иде — бездә гадәттәгечә сурәтләнә торган кыяфәттә: ягъни каты чирле, хәлсез, бетәшкән тавышлы, вакытыннан элек кабергә кергәндәй, тирән креслосына чумып утырган, үзенең акыл көче белән генә яшәүче һәм Европа белән көрәшеп киеренке уй сәләте белән генә сүрелдерми килүче бөкшәйгән бер карт түгел, бәлки үзенең шул еллардагы чын кыяфәтендә: ягымлы мөгамәләле, житез, чая бер кавалер иде, шул чагында ук инде, тән саулыгы булмаса да, ул үзен заманының иң атаклы бер кешесе иткән бетмәс-төкәнмәс рух көче белән яши иде. Герцог Неверлегә Манту биләмәләрендә ярдәм итеп, Ним, Кастр һәм Юзесны яулап алганнан соң, ул инглизләрне Ре атавыннан куарга һәм Ларошельне камап алырга җыена иде.

Шулай итеп, беренче карашка анын кардинал икәнлеген белгерткән бер сыйфаты да күренеп тормый, аны танып белмәгән кеше үз каршында кем икәнлеген аерып әйтә дә алмас иде.

Бичара галантерейчы керү белән ишек төбендә туктап калды, әле генә без тасвир иткән кеше исә, анын гомер тирәнлегенә үтеп керергә теләгәндәй, үткен карашын тоткынга батырды.

— Теге Бонасье шушымы? — диде ул беравык эндәшми торганнан соң.

— Әйе, галиҗәнап,— диде офицер.

— Яхшы. Сез миңа анын кәгазьләрен бирегез дә чыгып торыгыз.

Офицер соралган кәгазьләрне өстәлдән алып бирде дә баш иеп чыгып китте.

Бонасье бу кәгазьләрне таныды: Бастилиядә үзеннән сорау алу беркетмәләре иде бу. Камин янында басып торган кеше ара-тирә кәгазеннән аерылып, тоткынга күз салгалый һәм шул чагында бичара Бонасьеның йөрәгенә берьюлы ике хәнҗәр кадалган сыман тоела иде.

Ун минут чамасы укып, ун секунд чамасы күзәткәннән соң, кардиналга барысы да аңлашылды.

— Бу адәмчекнең бернинди заговорга катнашканы юк. Шулай да карап карыйк,— дип пышылдады ул үзалдына.

— Сез дәүләткә хыянәт итүдә гаепләнәсез,— диде кардинал сүзләрен салмак кына тезеп.

— Миңа ул хакта әйттеләр инде, галиҗәнап! — диде Бонасье, әңгәмәдәшенә әле генә теге офицер олылаганча олылап эндәште.— Ләкин ант итеп әйтәм: мин берни дә белмим.

Кардинал елмаюын тыеп калды.

— Сез хатыныгыз белән, де Шеврез ханым һәм герцог Бекингэм белән бергәләп заговор корган булгансыз.

— Чыннан да, галиҗәнап, хатынымның минем алда ул исемнәрне атап әйткәне булды,— диде Бонасье.

— Нинди уңай белән әйткән иде?

— Кардинал де Ришелье герцог Бекингэмны, аның белән бергә королеваны да харап итү өчен, Парижга алдап китерде, диде.

— Нәкъ шулай дип әйттеме? — дип ярсып кычкырып җибәрде кардинал.

— Әйе, нәкъ шулай дип әйтте, галиҗәнап, әмма мин шунда аның үзенә әйттем: андый нәрсәләр сөйләмә, кардинал хәзрәтләре андый эшкә сәләтле...

— Туктагыз, тыелыгыз, ахмак! — диде кардинал.

— Хатыным да миңа нәкъ шушы сүзне әйтте, галиҗәнап.

— Хатыныгызны кем урлаганлыгы сезгә мәгълүмме?

— Мәгълүм түгел, галиҗәнап.

— Кемнәндер шикләнәсез түгелме соң сез?

— Әйе, галиҗәнап. Тик минем ул шигем комиссар әфәндегә ошамады булса кирәк, шуңа күрә мин аннан ваз кичтем.

— Сезнең хатыныгыз качкан, анысын белә идегезме?

— Юк, белми идем, галиҗәнап. Мин ул хакта төрмәдә капитан әфәнде аша гына белдем. Бик йомшак мөгамәләле кеше икән.

Кардинал икенче тапкыр елмаюын тыеп калды.

— Димәк, хатыныгызның кая качып китүе сезгә мәгълүм түгел?

— Берни мәгълүм түгел, галиҗәнап. Луврга кайткандыр.

— Төнге сәгать бердә анда кайтмаган булган әле.

— Ай аллам! Нәрсә булды икән аңа?

— Борчылмагыз, анысы беленер. Кардинал белми кала торган нәрсә юк ул. Кардинал барысын да белә.

— Алай булгач, галиҗәнап, сез ничек уйлыйсыз: кардинал миңа хатынымның кайда икәнлеген әйтергә риза булмас микән?

— Бәлки, риза да булыр. Тик иң элек сез хатыныгыз белән де Шеврез ханым арасында нинәр барлыгын сөйләп бирергә тиешсез.

— Галиҗәнап, мин бит ул хакта берни белмим. Ул ханымны минем бер тапкыр да күргәнем булмады.

— Сез хатыныгызны алырга Луврга килгәч, ул туп-туры өегезгә кайтып китә идеме?

— Беркайчан да диярлек туры кайтканы булмады. Аның киндидер киндер белән сату итүчеләргә йомышы була, мин аны шунда озата бара идем.

— Ә ул киндер белән сату итүчеләр ничәү соң?

— Икәү, галиҗәнап.

— Кайда торалар?

— Берсе Вожирар урамында, икенчесе Лагарпта.

— Хатыныгыз белән бергә аларга кергәнегез булдымы?

— Бер дә булмады. Мин аны тышта көтеп тора идем.

— Ә ул аларга үзе генә керергә теләвен ни дип аңлата иде соң?

— Берничек тә аңлатып тормый иде. Мине көтеп тор, дия дә мин көтеп тора идем.

— Сез бик күндәм ир икәнсез, кадерле Бонасье әфәнде! — диде кардинал.

«Мине кадерле Бонасье дип атады. Эшләр яхшыга бара бит, шайтан алгыры!» — дип уйланды галантерейчы.

— Ул кергән ишекләрне хәтерлисезме?

— Хәтерлим.

— Номерларын исегездәме?

— Исемдә.

— Әйтегез әле.

— Вожирар урамындагысы егерме бишенче, Лагарп урамындагысы җитмеш беренче.

— Яхшы, — диде кардинал һәм өстәлдән көмеш кыңгырау алып чыңгылдатты. Бүлмәгә теге офицер керде.

— Рошфорны чакырып китерегез, — дип боерды Ришелье әкрен генә, — кайткан булса, хәзер үк килеп җитсен.

— Граф бирелә. Сез галиҗәнап хәзрәтләреннән үзен кабул итүегезне үтенә ул, — диде офицер.

— Керсен. Керсен! — дип кычкырды кардинал.

Кардиналның башка хезмәтчеләре аның боерганын ничек йөгереп үтәп йөрсәләр, офицер да шундый ук җитезлек белән бүлмәдән йөгереп чыгып китте.

«Галиҗәнап хәзрәтләре!» — дип пышылдады Бонасье, куркулан күзләрен акайтып.

Офицер чыгып, биш секунд та узмагандыр, ишек ачылып, бүлмәгә яңа кеше килеп керде.

— Шул үзе! — дип кычкырып җибәрде Бонасье.
— Кем ул «шул үзе»? — диде кардинал.
— Шул, минем хатынны урлаучы!

Кардинал тагын кыңгырау чыңгылдатты. Офицер килеп керде.

— Бу кешене алып чыгыгыз да китергән солдатларга тапшырыгыз. Мин яңадан чакырганчы көтеп торсын.

— Түгел, галиҗәнап, түгел, ул кеше түгел бу! — дип кычкыра башлады Бонасье.— Ялгышканмын мин. Хатынымны башка кеше урлады, бөтенләй моңа охшамаган кеше урлады. Бу әфәнде — намуслы кеше!

— Бу тинтәкне алып чыгыгыз! — диде кардинал.

Офицер Бонасьены беләгеннән тотып алгы бүлмәгә алып чыкты, анда аны сакчылар көтеп тора иде.

Әле генә кардинал янына кергән кеше Бонасьены түземсез бер караш белән озатып калды да, ишек ябылуга, тиз-тиз генә кардинал янына килде.

— Күрешкәннәр алар,— диде.
— Кемнәр? — дип сорады кардинал.
— Королева белән герцог.
— Королева белән герцог?! — диде Ришелье гаҗәпләнеп.
— Әйе.
— Кайда күрешкәннәр?
— Луврда.
— Ышанып әйтәсезме?
— Бернинди шик-шөбһәсез.
— Кем әйтте сезгә?
— Де Ланнуа ханым, белгәнегезчә, сез галиҗәнап хәзрәтләренә җаны-тәне белән бирелгән ул.
— Нигә ул моны алданрак әйтмәгән?
— Шулай килеп чыккандырмы, шикләнүләндерме — королева де Сюржи ханымга үзенең йокы бүлмәсендә куна калырга кушкан, аннары аны көн буе җибәрмәгән.
— Алай... Без җиңелдек. Үчне кайтарырга тырышырбыз.
— Сез галиҗәнапларга ярдәм итү өчен бөтен көчемне куеп тырышачакмын. Һич шикләнмәгез.
— Ничек булган ул хәл?
— Төнге беренче яртыда королева үзенең сарай дамалары белән утырганда.
— Кайда?
— Йокы бүлмәсендә.
— Яхшы.
— ...Кинәт аңа кастелянкасы җибәргән кулъяулыгы тапшыралар...
— Шуннан?
— Королева шундук бик дулкынлана башлый һәм, иннек-кершән сөртенгән булуына карамастан, йөзе агарынып китә...
— Шуннан? Шуннан?

— Шуннан, урыныннан тора да ят бер тавыш белән әйтә: «Мине бер ун минут көтеп торыгыз, мин хәзер киләм»,— ди. Шуннан инде ишекне ачып чыгып китә.

— Де Ланнуа ханым бу хакта нигә шундук сезгә хәбәр итмәгән?

— Башта ул әле моңа ышанып житмәгән. Өстәвенә, королева: «Мине көтеп торыгыз»,— дигән бит. Ул инде аны тыңламыйча булдыра алмаган.

— Королева күпме вакыт югалып торган?

— Кырык биш минут чамасы.

— Сарай дамаларыннан берәрсе аны озата чыкмаганмы?

— Донья Эстефания генә озата чыккан.

— Аннары королева кире кергәнме?

— Әйе, ләкин үзенең монограммасы төшерелгән алсу тартмасын алган да тагын чыгып киткән.

— Кире кергәндә тартмасы кулында булганмы соң?

— Кулында булмаган.

— Тартмада ниләр булганлыгын де Ланнуа ханым беләме?

— Белә. Королевага король галиҗәнаплары бүләк иткән асылташлары булган.

— Кергәндә шул тартмасы кулында булмаганмы?

— Әйе.

— Димәк, де Ланнуа ханым, королева тартманы герцог Бекингэмга биргән, дип уйлый?

— Аның моңа берниндн шиге юк.

— Нигә?

— Көндез де Ланнуа ханым, королеваның камерфрейлинасы буларак, тартманы бөтен җирдән эзләп чыга, тартманың югалуына бик борчылган булып күренә, ахырында королевадан: «Тартманың кая юкка чыкканын белмисезме?» — дип сорый.

— Шуннан королева нәрсә ди?..

— Королева кып-кызыл булып кызарынып китә, кичә бер асыл ташым ватылган иде, ювелирга төзәттерергә җибәрдем, ди.

— Корольнең ювелирына кереп, белешергә кирәк: шул хәл дөресме, түгелме.

— Мин кереп белештем инде.

— Я? Ни диде соң ювелир?

— Ювелирның ишеткәне дә юк икән.

— Бик шәп! Бик шәп, Рошфор! Өмет бөтенләй үк бетмәгән әле, кем белә бит, кем белә... бәлки, эшләр яхшыга таба барадыр.

— Мин тамчы да шикләнмим: сез галиҗәнап хәзрәтләренең даһилыгы...

— ...үз шымчысының хатасын төзәтер дисезме, шулаймы?

— Сез галиҗәнап хәзрәтләре сүземне әйтеп бетерергә мөмкинлек биргән булса, мин нәкъ шулай димәкче идем.

— Ә хәзер... герцогиня де Шеврез белән герцог Бекингәмнең кайда яшеренеп ятулары сезгә мәгълүмме?

— Юк, галиҗәнап, шымчыларым ул хакта бернинди дә анык мәгълүмат хәбәр итә алмадылар.

— Ә мин менә беләм.

— Сез беләсез, галиҗәнап?

— Әйе. Һәрхәлдә, чамалыйм.

— Галиҗәнап хәзрәтләре аларның икесен дә кулга алдыруымны теләмиме?

— Хәзер соң инде. Алар китеп өлгергән булырга тиешләр.

— Һәрхәлдә, тикшереп карарга була...

— Үзегез белән минем ун гвардиячемне алыгыз да ике йортны да тентеп чыгыгыз!

— Боерыгыгыз үтәлер, галиҗәнап хәзрәтләре.

Шулай дигәч, Рошфор ашыгып чыгып китте.

Кардинал, ялгызы калгач, беравык уйланып торды да өченче тапкыр кыңгырау чыңгылдатты.

Ишектә шул ук офицер күренде.

— Тоткынны кертегез! — диде кардинал.

Бонасье әфәндене тагын кабинетка керттеләр. Кардинал ишарәсенә буйсынып, офицер кабинеттан чыгып китте.

— Сез мине алдагансыз,— диде кардинал кырыс бер төс белән.

— Мин? — дип кычкырып сорады Бонасье.— Мин галиҗәнап хәзрәтләрен алдаганмынмы?

— Хатынызгыз Божирар урамы белән Лагарп урамына баргач, бөтенләй киндер белән сату итүчеләр янына кермәгән бит.

— И аллам, кемнәр янына керде икән соң ул?

— Герцогиня де Шеврез һәм герцог Бекингәм янына кергән ул.

— Әйе, әйе, дөрес, сез галиҗәнап хәзрәтләре хаклы,— диде Бонасье, хәтерендәгеләрне исенә төшерергә тырышып.— Хатыныма берничә мәртәбә әйткәнем дә булды: киндер белән сату итүчеләрнең шундый вывескасыз йортта яшәүләре бик гаҗәп, дидем. Шулай дигән саен хатыным шаркылдап көлде генә. Һай, галиҗәнап,— диде Бонасье, кардинал хәзрәтләренең аягына егылып,— сез чыннан да кардинал бит, бөек кардинал, бөтен кешене баш идерүче даһи!

Бонасьеише бичара бер адәм затын баш идерүнең шатлыгы бик кечкенә булса да, кардинал бу хәлдән беравык ләззәт тоеп торды.

Аннары, башына яңа бер уй килгәндәй, кинәт авыз кырыйлары белән генә көлемсерәп куеп, галантерейчыга кулын сузды.

— Торыгыз, дустым. Сез инсафлы кеше,— диде.

— Кардинал минем кулыма орынды, мин бөек кешенең кулына орындым!.. Бөек кеше мине дустым дип атады!..— дип кычкырып сөйләнде Бонасье.

— Әйе, дустым, әйе! — диде кардинал аталарча бер тон белән — вакыт-вакыт ул үзен яхшы белмәгән кешеләрне генә алдый торган шундый тон белән дә сөйләшкәләп куя иде.— Сезне нахакка гаепләгәннәр, шуның өчен сезгә әҗер тиешле. Менә шушы янчыкны алыгыз, монда йөз пистоль акча бар, һәм сез мине кичерегез.

— Мин сезне кичерергә тиешме, галиҗәнап?! — диде Бонасье, акчалы янчыкка үрелергә йөрәге җитмәде, шаярталар гынадыр дип шикләнде, күрәсең.— Сез теләдегез — мине кулга алдыгыз, теләсәгез — мине газаплый-җәзалый аласыз, дарга аса аласыз, сез безнең хөкемдарыбыз, мин «ык» та итә алмас идем. Сезне кичерергәме, галиҗәнап?! Моны уйга китерү дә мөмкин түгел!

— Ах, кадерле Бонасье әфәнде, сез гаҗәеп олы җанлы бер кеше икәнсез! Шуны күреп, сезгә рәхмәтемне белдерәм. Шулай итеп, сез янчыкны аласыз да бериикадәр канәгатьлек белән кайтып китәсез.

— Мин сезгә сокланып, хәйран булып кайтып китәм.

— Ярый, сау булып торыгыз. Мин сезнең белән бөтенләйгә саубуллашмыйм әле, чөнки тагын да күрешербез дип өметләнәм.

— Сез галиҗәнап хәзрәтләре кайчан теләсә шунда! Сез галиҗәнап хәзрәтләренең кушканын үтәргә мин әзер.

— Бер дә борчылмагыз, без еш күрешкәләп торырбыз. Сезнең белән әңгәмә кылу минем өчен ифрат ләззәтле булды.

— О, галиҗәнап хәзрәтләре!..

— Сау булыгыз, Бонасье әфәнде, сау булыгыз!

Һәм кардинал кулы белән ымлауга, Бонасье җиргә чаклы бөгелеп баш иде. Аннары арты белән чигенә-чигенә бүлмәдән чыгып китте. Алгы бүлмәгә чыккач, кардинал аның: «Яшәсен галиҗәнап! Яшәсен галиҗәнап хәзрәтләре. Яшәсен бөек кардинал!» — дип шәрран ярып кычкырганын ишетте.

Метр Бонасьеның шулай шау-гөр килеп хисләрен белдерүен кардинал елмаеп тыңлап торды да Бонасьеның тавышы еракка китеп тынгач:

— Моннан соң инде бу кеше минем өчен җанын да аямас,— дип куйды.

Һәм бөтен игътибарын-дикъкатен туплап, өстәленә җәеп салынган Ларошель картасы өстенә иелде, карандашы белән моннан ел ярым элек камалуда калган шәһәрнең гаванена юлны бикләгән атаклы дамба сызыкларын сызарга кереште. Әнә шулай бик бирелеп стратегик планнары белән шөгыльләнгән чагында кинәт ишек ачылып, бүлмәгә Рошфор килеп керде.

Кардинал, җанланып китеп:

— Я, ничек? — дип сорады, аның шулай җәһәт кенә урыныннан күтәрелүе графка кушкан йомышына зур әһәмият бирүен күрсәтә иде.

— Әш болай,— дип сүзгә кереште граф.— Сез галиҗәнап хәзрәтләре әйткән йортларда, чыннан да, егерме алты-егерме сигез яшьләрендәге бер хатын һәм утыз биш-кырык яшьләрендәге бер ир торып киткәннәр. Ир кеше дүрт көн торган, хатын — биш көн. Хатын бүген төнлә киткән, ир кеше — иртә белән.

— Шулар булган! — дип кычкырып әйтеп куйды кардинал һәм стенадагы сәгатькә күз төшереп алды да:— Алар артыннан куа чыгарга хәзер соң инде — герцогиня Турга барып җиткән, ә герцог Бекингэм Булоньда. Аны Лондонда куып тотарга туры килер,— диде.

— Сез галиҗәнап хәзрәтләренең нинди әмерләре булыр соң?

— Бу хәл турында ләм-мим сүз ычкындырмаска. Королева берни дә шик-шөбһә тумасын, без аның серләрен ачканлыгыбызны ул белмәсен. Безне берәр төрле заговор ачу белән шөгыльләнәләр дип уйласын... Минем янга канцлер Сегьены чакырып китерегез.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, теге кешене нишләттегез соң?

— Нинди кешене? — дип сорады кардинал.

— Теге Бонасьены?

— Мин аның белән эшли алырга мөмкин булганны эшләдем. Мин аны шымчы иттем, үз хатыны артыннан шымчылык итәчәк ул.

Граф Рошфор хакименең буй җитмәс өстенлеген тәкъдир иткән бер төс белән баш иеп чыгып китте.

Кардинал, ялгызы калгач, янадан креслосына утырды, тиз-тиз генә хат язып, үз печәте белән печәтләп ябыштырды да кыңгырау чыңгылдатты. Дүртенче тапкыр шул ук дежур офицер килеп керде.

— Минем янга Витрене чакырып китерегез әле,— диде кардинал,— әйтегез үзенә: ерак юлга чыгып китәргә әзер булып торсын.

Берничә минуттан соң инде аның каршында, юлга чыгарга әзер булып, озын күнычлы, шпорлы ботфортлар кигән, чакырылган кеше басып тора иде.

— Витре,— дип сүзгә кереште Ришелье,— сез хәзер үк Лондонга китегез. Юлда беркайда да бер секундка да тукталып тормагыз. Менә бу хатны миледи кулына тапшырырсыз. Менә ике йөз пистоль акча бирү хакында боерык. Хәзер минем казначыга барыгыз да ул сезгә акчалата бирер. Минем йомышны яхшы үтәп, алты көндә әйләнеп кайтсагыз, үзегезгә дә шул чаклы акча тияр.

Йомышчы, бер сүз җавап кайтармастан, башын иеп, хат белән ике йөз пистоль акчалык чекны алды да бүлмәдән чыгып китте.

Хатта мондый сүзләр язылган иде:

«Миледи! Герцог Бекингэм катнашкан беренче балга ук барыгыз. Аның камзулына уникe асылташ тагылган булыр; янына барыгыз да ике асылташны кисеп алыгыз.

Асылташларны кулыгызга төшерү белән мина хәбәр итегез».

## XV

## *ГАСКӘРИЛӘР һӘМ ХӨКЕМЧЕЛӘР*

Шушы хәлләр булганнын икенче көнендә д'Артаньян белән Портос, Атосның һаман кайтмавын күреп, аның юкка чыгуы турында де Тревиль әфәндегә хәбәр иттеләр.

Арамиска килгәндә исә, аны, биш көнгә ял сорап, гаилә йомышлары белән Руанга киткән, имеш, дип сөйләделәр.

Де Тревиль әфәнде үз солдатлары өчен аталары кебек бер кеше иде. Арада күзгә дә чалынмаган, беркемгә билгеле булмаган солдат та, мушкетер киемен киеп алу белән, бертуган абыйсына ышанган кебек, капитанның ярдәменә ышанып яши иде.

Шуна күрә де Тревиль, Атосның югалу хәбәрен ишетү белән, җинаять эшләре буенча баш судья янына китте. Кызыл Тәре янындагы сакка башлык итүче офицерны чакырып китерделәр һәм, алынган мәгълүматларны эзлекләп тикшерә торгач, Атосның Фор-Левекка ябылган булуын белделәр.

Атос та шул ук Бонасье кичергән сынауларны үтте.

Күргәнебезчә, без ике тоткынны күзгә-күз очраштыруга катнаштык. Д'Артаньянны борчымасыннар, аңа иркенләп йөрергә комачауламасыннар дип, шуңарчы берни әйтмәгән Атос хәзер, минем исемем д'Артаньян түгел, бәлки Атос, диде.

Моннан тыш, мин Бонасье әфәндене дә, Бонасье ханымны да белмим, аларның берсе белән дә гомеремдә дә сөйләшкәнем юк, диде. Кичке сәгать уннар тирәсендә ул дусты д'Артаньян әфәнде янына хәл белешә кергән, ә шуңарчы де Тревиль әфәнде янында ашта булган. Моның шулай икәнлегеи егерме-ләп шаһит раслый ала икән. Шуннан соң Атос бернинә атаклы кешенең исемен әйтте, шулар арасында герцог де Ла Тремульны да телгә алды.

Беренчесе кебек, икенче комиссар да бу мушкетерның гади һәм салкын дәлилләре каршында аптырабрак калды. Югыйсә, гаскәри кеше белән көрәштә суд чиновниклары һәрвакыт җиңеп чыгарга тырышкан кебек, моның да мушкетердан өстен чыгарга теләге бик зур иде. Әмма, де Тревиль әфәнде белән герцог де Ла Тремуль исемнәрен ишеткәч, аптырашта калды.

Атосны да, Бонасье әфәнде кебек, кардинал янына алып бардылар, тик, кызганычка каршы, кардинал Луврга — король янына киткән булып чыкты.

Нәкъ шушы вакытта исә де Тревиль әфәнде җинаять эшләре буенча баш судья белән Фор-Левек коменданты яныннан чыгып, Атосны күрергә рөхсәт ала алмыйча, король янына килгән иде.

Мушкетерлар капитаны буларак, де Тревиль әфәнде корольнең теләсә кайчан күрә ала иде.

Белгәнебезчә, король королевага ышанмый, аннан бик нык шикләнә, интригалар мәсьәләсендә ирләргә караганда хатын-кыздан күбрәк шөбһәләнгән кардинал исә бу шикне оста рәвештә яңартып, үстереп тора иде. Аның Анна Австриялегә шикләнеп каравының төп сәбәпләреннән берсе королеваның де Шеврез ханым белән дус булуы иде. Испания белән ике арадагы сугышларга, Англия белән ике арадагы аңлашылмаучылыкларга һәм финанс мәсьәләләренең чуалчыклыгына караганда да бу ике хатын аны күбрәк борчый иде. Кардиналның фикеренчә һәм ихлас күңеленнән ышануынча, де Шеврез ханым королевага политик интригаларда гына булышып калмый, бәлки — кардиналны иң нык борчыганы — мәхәббәт интригаларында да ярдәм итә иде.

Кардинал, сүзгә керешеп, Тур каласына сөрелгән һәм шунда яшәргә тиешле булган де Шеврез ханымның яшерен рәвештә Парижга килүен һәм монда биш көн торып, полициянең башын әйләндерүен әйтү белән үк, король ярсып-кызып китте. Король, тиккере һәм мәкерле бер кеше булса да, үзен Гадел Людовик, Пакь Людовик дип атауларын тели иде. Тарих гыйлеме тарафыннан, фикер йөртмичә, бик күп фактлар китереп кенә аңлатырга тырышылган бу характерга киләчәк буыннар зур кыенлык белән генә төшенерләр.

Де Шеврез ханым Парижга килеп кенә калмаган, ул заманда каббалистик дип аталган шифр ярдәмендә королева аның белән бәйләнешен яңарткан икән. Кардинал инде бу интриганың иң нечкә җепләрен сүтәргә әзерләнеп беткәч һәм читкә сөрелгән ханым белән королева арасында арадашлык итүче хатынны, барлык дәлилләр белән коралланып, җинаяте өстендә кулга алырга җыенгач, ниндидер бер мушкетер суд тикшерүе барышын көчләп туктатырга батырчылык иткән һәм корольгә хәбәр итү өчен шушы эшне гаделлек белән тикшерү бурычы тапшырылган намуслы чиновниклар өстенә кылычы белән ташланган. Кардинал әнә шуларны сөйли башлагач инде, Людовик XIII бөтенләй чыгырыннан ук чыкты. Ярсудан сүзен әйтә алмыйча (дуамал ярсуы ташып киткән чакларында бу монарх үзен иң рәхимсез эшләр эшләргә дә сәләтле итеп тоя иде), көл төсле агарынып, ул королева апартаментларына керә торган ишеккә таба бер-ике адым атлап куйды. Хәлбуки, кардинал әле Бекингэмның исемен телгә алырга өлгермәгән иде.

Нәкъ әнә шул вакытны килеш-килбәтенә карата бер сүз дә әйтмәслек сабыр гына, әдәпле генә бер төстә де Тревиль килеп керде. Бирелә кардиналны күргәч, кашы-күзе жимерел-

гән корольнең чыраена күз дә төшереп алгач, де Тревиль монданиләр булганлыгын шундук төшенде һәм үзен, филистимләләр каршындагы Самсон кебек, көчле итеп хис кылды.

Людовик XIII инде ишек тоткасына тотынгач, де Тревильнең аяк тавышын ишетеп борылып карады.

— Бик вакытлы килдегез,— диде король, ачу-ярсуларына артык бирелеп киткәнлектән, ул инде эчендәген тыеп калырлык хәлдә түгел иде.— Сезнең мушкетерларыгыз хакында бик күңелле нәрсәләр сөйлиләр миңа!

— Ә миндә сез галиҗәнапларга хөкемчеләрегез хакында сөйләрлек шактый яхшы нәрсәләр бар,— дип салкын гына җавап кайтарды де Тревиль.

— Аңламыйм мин сезне,— диде король тәкәббер бер тон белән.

— Сез галиҗәнапларга мәгълүм булсын,— дип сабыр гына сүзендә дәвам итте де Тревиль,— бер төркем чиновник, комиссар һәм полицейскийлар, бик мөхтәрәм кешеләр, гаскәриләргә дошман итеп караучылар, күрәсең,— минем бер мушкетерымны, дөресрәге — сезнең бер мушкетерыгызны, галиҗәнап, бик әдәпле, тәртипле, мин әйтер идем — дан казанган, сез галиҗәнапларга иң яхшы яклары белән таныш булган Атос әфәндене бер йортта кулга алганнар да ачыктан-ачык урам буйлап алып китеп Фор-Левекка илтеп япканнар, моны без боерык нигезендә эшләдек, диләр, үзләре ул боерыкны миңа күрсәтергә риза булмадылар.

— Атосны,— дип ихтыярсыз гына әйтеп куйды король,— ул исем таныш кебек миңа...

— Сез, галиҗәнап, исегезгә төшерергә тырышып карагыз әле,— диде де Тревиль.— Атос әфәнде ул — сезгә мәгълүм булган теге хәерсез дуэльдә, бәхетсезлегенә каршы, де Каюзак әфәндене каты яралаган мушкетер... Яралаган дигәннән, галиҗәнап хәзрәтләре,— диде де Тревиль кардиналга мөрәҗәгать итеп,— Каюзак әфәнде сәламәтләнеп җиткәндер бит инде?

— Әйе, рәхмәт,— дип кенә куйды кардинал, ачудан иренен тешләп.

— Шулай итеп, Атос әфәнде үзенең дусты янына, сез галиҗәнап гвардиясенең кадеты, Дезэссар ротасында хезмәт итүче бер Беарн егете янына хәл белергә керә. Егет өйдә туры килми. Шуннан Атос әфәнде, дусты кайтканын көтим дип, урындыкка утырып, кулына китап алырга да өлгерми — бер көтү шымчы һәм солдат йортны камап алалар да берничә ишекне ваталар...

Кардинал корольгә ишарәләп кенә: «Мин әле генә сезгә сөйләгән хәлгә кагылышлы бу...» дигән мәгънәне аңлатты.

— Болар барысы мәгълүм безгә. Чөнки болар безнең файда хакына эшләнгән,— диде король.

— Шулай итеп,— дип сүзендә дәвам итте де Тревиль,— сезнең файда хакына минем һичбер гаепсез мушкетерымны тотып

кулга алганнармы? Сезнең файдага хакына аны ике солдат сагы астында шәһәр урамнарыннан алып киткәннәр, сез галиҗәнап өчен уннарча тапкыр кан койган һәм тагын да теләсә кайчан кан коярга әзер торган саф намуслы бер кешене урам халкы мыскыллап калганмы?

— Ни сөйлисез сез! — дип куйды король икеләнә башлап.— Шулай сез сөйләгәнчә булганмыни ул хәл?

— Де Тревиль әфәнде шул бер гаепсез мушкетерның, саф намуслы кешенең, аңарчы бер сәгать элек кенә гадәттән тыш мөһим бер эш буенча минем тарафтан тикшерергә җибәрелгән дүрт комиссар өстенә кылычы белән ташланганын сезгә әйтми калдырды,— диде кардинал, искиткеч бер сабырлык саклап.

— Галиҗәнап хәзрәтләре моны исбат итсен! — диде де Тревиль, Гасконь кешеләренә генә хас ихласлык һәм гаскәриләргә хас кискенлек белән.— Хикмәт шунда ки: аңарчы бер сәгать элегрәк Атос әфәнде,— сез галиҗәнапларга әйтсәм әйтим,— шактый этаклы нәселдән чыккан бер кеше, миндә аш мәҗлесендә булып, кунак булмасендә герцог де Ла Тремуль һәм граф де Шәлю белән әңгәмә кылып утырды.

Король кардиналга карады. Аның сүзсез соравына каршы кардинал:

— Мин сөйләгәннәрнең барысы да һөҗүмгә дучар булучылар тарафыннан язылган беркетмәгә теркәлгән. Сез галиҗәнапка мин аны китереп күрсәтермен,— дип җавап бирде.

— Суд чиновникларының беркетмәсе гаскәриләрнең тугры сүзенә тәрлык микән? — дип сорады де Тревиль горур бер төс белән.

— Житәр, житәр, де Тревиль, тик кенә торыгыз! — диде король.

— Әгәр кардинал хәзрәтләре минем берәр мушкетерымнан шикләнә икән,— кардинал хәзрәтләренең гаделлеге һәркемгә мәгълүм бит,— ул чагында мин үзем хәлне тикшерүегезне сорыйм, — дип җавап кайтарды де Тревиль.

— Тенту ясалган йортта, хәтерем ялгышмаса, бер Беарн егете, әлеге мушкетерның дусты яши шикелле? — диде кардинал сабыр гына.

— Галиҗәнап хәзрәтләре д'Артаньянны күздә тотып әйтәме?

— Де Тревиль әфәнде, сез химаячелек итә торган егетне күздә тотып әйтәм мин.

— Әйе, химаячелек итүем дөрес, галиҗәнап хәзрәтләре.

— Сез шундый хәлнең булуы да ихтимал дип санамыйсызмы: әлеге егетнең әшәке йогынтысы...

— ...үзеннән бермә-бер олы Атос әфәндегә йокмаганмы? — диде де Тревиль, кардиналның сүзен бүлеп.— Юк, галиҗәнап, андый хәлнең булуы мөмкин дип санамыйм мин. Өстәвенә, д'Артаньян әфәнде дә ул кичне миндә булды.

— Менә сиңа тамаша! — дип куйды кардинал.— Бөтенесе дә ул кичне сездә булганнар, күрәсең!

— Галиҗәнап хәзрәтләре минем сүземә ышанмый булса кирәк? — диде де Тревиль, ачуыннан битләренә кан йөгерде.

— Юк, ышанам, алла сакласын! — диде кардинал.— Ә д'Артаньян сәгать ничәдә булды сезгә?

— О, анысын мин сез галиҗәнап хәзрәтләренә төп-төгәл әйтә алам: ул килеп кергәндә, вакыт инде шактый соңдыр кебек тоелса да, сәгать унынчы ярты гына икәнен искәреп калдым.

— Ә ул сездән сәгать ничәдә чыгып китте?

— Унберенче яртыда. Әлеге хәлләрдән соң бер сәгать узгач.

— Әмма шуңа карамастан,— диде кардинал, җиңү кулдан ычкынып барганлыгын тоеп,— шуңа да карамастан, Атосны Каберчеләр урамындагы әлеге йортта кулга алганнар бит.— Де Тревиль сүзләренең дөреслегенә тамчы да шикләнми иде ул.

— Кешегә дусты янына хәл белешә барырга, минем ротаның мушкетерына Дезэссар әфәнде ротасындагы гвардияче белән туганнарча дуслык багланышы тотарга ярамыймыни?

— Күрешә торган дустының йорты шикле булмаса — ярый.

— Хикмәт шунда: әлеге йорт шикле йорт бит, Тревиль. Сез анысын, бәлки, белмәгәнсездер,— дип сүзгә король дә кушылды.

— Әйе, галиҗәнап, анысын мин чыннан да белми идем. Шулай да әлеге шик ул йортның д'Артаньян әфәнде яшәгән өлешенә кагылмыйдыр дип уйлыйм, чөнки, ихлас күңелемнән әйтәм, сез галиҗәнапларга аның кебек тугры хезмәт итүче, кардинал хәзрәтләрен аның кебек тирәнтен ихтирам итүче юктыр.

— Бервакыт кармелиткалар монастыре янында сугышканда де Жюссакны шул д'Артаньян яралаган иде түгелме? — дип сорады король, ачудан кызарынган кардиналга карап алып.

— Ә иртәгесе көнне Бернажуны җиңгән иде,— дип өстәп куйды де Тревиль.— Әйе, галиҗәнап, шул егет үзе; сез галиҗәнапларның хәтере искиткеч яхшы икән.

— Я, ничек хәл иттек инде? — дип сорады король.

— Анысы миннән бигрәк сез галиҗәнапларның эше инде,— диде кардинал.— Мин ул Атосны гаепле дип саныйм.

— Ә мин моны инкяр итәм,— диде де Тревиль.— Галиҗәнапның судьялары бар, бу эшне судьялар тикшерсен.

— Бик дөрес,— диде король дә.— Бу эшне судьяларга тапшырыйк. Аларның эше — хөкем итү, алар хөкем итсен.

— Шулай да бик күңелсез хәл инде,— дип, де Тревиль яңадан сүзгә кереште.— Безнең заман кебек шундый бәхетсез бер заманда иң пакь тормыш та, чын игелек тә кешене мәсхәрә ителү вә җәбердән аралап кала алмый, ихластыр, нинди дә полиция мажаралары аркасында каты эзәрлекләүгә дучар була башлавына армия дә бигүк риза булмас.

Де Тревиль саксызрак сүзләр ычкындырды. Әмма бу сүзләренең көчен белеп әйтте ул. Де Тревиль шулай дип әйтеп шартлау хасил итәргә теләде, шартлау исә ут-ялкын бөркеп, бөтен тирә-якны яктыртып җибәрә.

— Полиция маҗаралары! — дип кычкырды король, де Тревиль сүзенә ябышып.— Полиция маҗаралары! Ул турыда нәрсә беләсез сез, әфәндем? Әнә үзегезнең мушкетерларыгыз белән генә шөгыльләнегез, минем башымны катырмагыз! Сезне тыңласаң, бер мушкетерны кулга алу белән бөтен Франция куркыныч астында калган икән дип уйларсың. Ниндидер бер мушкетер аркасында күпме шау-шу чыгарасыз. Шайтан алгыры, теләсәм, мин аларны дистәләп кулга алдырырмын! Йөзләп! Ротасы белән! Һәм беркем дә «ык» та итә алмас!

— Әгәр сез галиҗәнапка мушкетерлар шикле тоела икән, димәк, алар гаепле,— диде де Тревиль.— Шуңа күрә мин кылычымны сезгә кайтарып бирергә әзермен, галиҗәнап. Чөнки минем солдатларымны гаепле иткәннән соң, кардинал әфәнде, һичшиксез, ахыр чиктә миңа каршы да гаеп табачак. Шул сәбәпле мин үземне дә Атос әфәнде белән,— ул кулга алынган инде — һәм д'Артаньян әфәнде белән — ихтимал, якын арада аныСын да кулга алырлар — алар белән бергә кулга алынган дип санасам яхшырак булыр.

— Гасконь киресе, туктыйсызмы-юкмы?! — дип кычкырды король.

— Галиҗәнап,— диде де Тревиль, тавышын бер дә йомшартмыйча,— я мушкетерымны кайтарсыннар миңа, я аны хөкем итсеннәр.

— Аны хөкем итәчәкләр,— диде кардинал.

— Алай булса — бик яхшы. Ул чагында сез галиҗәнаптан аны якларга рөхсәт сорыйм.

Король ике арада ут чыгудан курка иде.

— Әгәр кардинал хәзрәтләренең шәхсән сәбәпләре булмаса...— дип сөйләнеп куйды ул.

Кардинал корольнең тел төбен аңлады, шуңа күрә алдан ук әйтеп куйды:

— Гафу итәсез, әгәр галиҗәнап мине гадел була алмый дип саный икән, ул чагында мин хөкемгә катнашудан баш тартам,— диде.

— Минә нәрсә,— диде король,— әлеге хәлләр вакытында Атос миндә булды, ул хәлләргә катнашмады дип, минем атам исеме белән ант итегез.

— Сезнең шанлы атагыз исеме белән һәм дөньяда иң хөрмәт иткән, иң яраткан кешем — сезнең исемегез белән ант итәм!

— Уйлап карагыз әле, галиҗәнап. Әгәр без тоткынны азат итсәк, дөресләкне белми калачакбыз бит,— диде кардинал.

— Атос әфәнде һәрвакыт үз урынында булачак һәм судья әфәнделәр сорау аларга кирәк дип тапкан вакытта җавап би-

рергә әзер булып торачак. Беркая да качмас ул, кардинал әфәнде, анысы өчен борчылмагыз. Аның өчен җаваплылыкны үз өстемә алам,— диде де Тревиль.

— Чыннан да, качмас шул,— диде король килешеп.— Де Тревиль әфәнде әйтмешли, аны теләсә кайчан табып булыр. Аннан ары,— диде король тавышын әкренәйтә төшеп һәм ялварган бер төс белән кардиналга карады,— аларны тынычсызламабыз да, иң яхшы политика булыр ул.

Людовик XIII нең бу политикасы Ришельены елмаерга мәҗбүр итте:

— Әмерегезне бирегез, галиҗәнап. Сезнең кичерү хокукыгыз да бар бит.

— Кичерү хокукын гаепле кешегә карата гына кулланалар,— диде де Тревиль, соңгы сүзне үзе әйтергә тырышып.— Ә минем мушкетер гаепле түгел. Шуңа күрә король галиҗәнаплары аны кичерми, бәлки аңа карата гаделлек эшли.

— Фор-Левектамы ул? — дип сорады король.

— Әйе, галиҗәнап, ялгызлар камерасында, иң әшәке бер җинаятьче кебек, тышкы дөнья белән багланыш тоту хокукыннан мәхрүм ителгән.

— Шайтан алгыры! Нишләргә соң? — дип сөйләнде король.

— Азат итәргә дип боерык язып кул куярга да вәссәлам,— диде кардинал.— Мин дә, галиҗәнап, нәкъ сезнеңчә уйлыйм һәм де Тревиль әфәндедән җаваплылыкны үз өстенә алуы моның өчен бик җиткән дип саныйм.

Тревиль бу хәлгә бик сөенеп бетте иде, тик шатлык белән бергә күңеленә шом да керә башлады. Кардиналның болай һич көтмәгәндә юл куюына караганда аяк терәп каршы торуын яхшырак күрә иде ул.

Тоткынны азат итү турындагы боерыкка король кул куйгач, де Тревиль, боерыкны алып, тизрәк чыгып китәргә ашыкты.

Ул инде ишектән чыгып барганда, кардинал аңа карап ягымлы бер чырай белән елмайды да корольгә мөрәҗәгать итте:

— Галиҗәнап, сезнең мушкетерларыгызда солдатлар белән башлыклары арасында нинди шәп татулык яши! Бу хәл гаскәри хезмәт өчен бик файдалы, бөтен ротаның абруен күтәрә,— диде.

«Шик юк: якын арада ул миңа берәр этлек эшләргә тырышачак,— дип уйланды де Тревиль.— Аның ни уйлаганын һич белә алмассың. Әмма ашыгырга кирәк. Король теләсә кайчан карарын үзгәртеп куюы да ихтимал, ә менә яңа гына иреккә чыккан кешене кире Бастилиягә яки Фор-Левекка илтеп ябу анда утырган тоткынны чыгармый калуга караганда кыенрак эш».

Де Тревиль әфәнде тантаналы бер төс белән Фор-Левекка барып керде дә һаман да тынычлыгын, сабырлыгын җуймаган Атосны тоткынлыктан азат итте.

Д'Артаньянны беренче очратуында ук де Тревиль әйтте:

— Бу юлы сез бәхетле булып чыктыгыз. Сездән де Жюссакны яралаган өчен үч алдылар. Бернажуның җинелүе өчен үч кайтарасылары бар әле. Сак булыгыз,— диде.

Кардиналга ышанмыйча, алла күрәшәсе бар әле дип уйлавы белән де Тревиль, әлбәттә, хаклы иде. Мушкетерлар капитаны артыннан ишек ябылу белән ук кардинал хәзрәтләре корольгә таба борылды да:

— Менә хәзер, икәүдән-икәү генә калгач, сез галиҗәнап кирәк дип тапсагыз, бик мөһим нәрсәләр хакында сөйләшәбез. Галиҗәнап! Герцог Бекингәм бии көн буена Парижда торып, бүген иртә белән генә китеп барган,— диде.

## XVI

## КАНЦЛЕР СЕГЬЕНЫҢ КАГА ТОРГАН ЧАҢЫН ТАБА АЛМАВЫ

Бу сүзләрнең Людовик XIII гә никадәр көчле тәэсире булганлыгын күз алдына китерүе дә кыен хәтта. Ул башта кызарынып китте, аннары шундук йөзе агарып калды. Һәм кардинал әле генә югалткан позицияләрен бер сугу белән кайтарганлыгын аңлады.

— Герцог Бекингәм Парижга килгән! — дип әсәрләнеп әйтеп куйды король.— Нигә килгән соң ул монда?

— Дошманнарыбыз испаннар һәм һугенотлар белән сөйләшеп безгә каршы сүз берләштерү өчендер.

— Түгел! Валлаһи, түгел! Де Шеврез ханым, де Лонгвиль ханым һәм Конделарның барысы белән сүз берләштереп мине хур итәр өчен килгән ул!

— Галиҗәнап! Ничек сез андый уйны башыгызга китерә аласыз! Королева шундый акыллы, сак хатын, аннан да бигрәк — сез галиҗәнапны бик ярата бит ул.

— Хатын-кыз таз бирешүчән ул, кардинал әфәнде. Олы мәхәббәт дигәнгә килгәндә исә, ул мәсьәләгә минем үз карашым бар.

— Шулай да мин үз фикеремне куәтләп әйтәм: герцог Парижга саф сәяси максатлар белән килгән,— диде кардинал.

— Ә минемчә, бөтенләй башка максатлар белән килгән. Әгәр дә мәгәр гаебе булса, королевага бик яман булачак бит!

— Чыннан да,— дип сүзгә кереште кардинал,— андый хәл булуы ихтимал дип уйлавы никадәр авыр булса да... Сез галиҗәнап бер нәрсәне исемә төшердегез: де Ланнуа ханым,— сез галиҗәнап боерыгы нигезендә мин аннан берничә тапкыр сорау алган идем,— де Ланнуа ханым бүген иртән миңа шуларны әйтте: узган төннең алдагысында королева йокларга бик соң яткан, бүген иртән бик озак елаган, көн буе хат язган.

— Барысы да аңлашылды! — диде король.— Әлбәттә, хатны тегенә язган! Кардинал, королеваның бөтен хат-кәгазьләрен табып китерегез миңа.

— Галиҗәнап, ничек тапмак кирәк ул хатларны? Минемчә, андый эшне мин дә, сез галиҗәнап та үз өстенә ала алмый.

— Ә маршал д'Анкр хатыны белән ничек эш кылдыгыз соң? — диде король, ярсуын тыя алмыйча.— Шкафларын тентедегез, ахырда үзен дә тентедегез.

— Маршал д'Анкр хатыны — маршал д'Анкр хатыны гына шул ул, Флоренциядән килеп маҗара эзләп йөрүче бер ханым гына, ә сез галиҗәнапның олуг хөрмәтле хатыны — Анна Австрияле ул, Франциянең королевасы, ягъни дөньяда иң бөек патша хатыннарының берсе.

— Шуңа күрә аның гөнаһысы да яманрак, герцог! Ул дәрәҗәсенең олуглыгын никадәр тиз оныткан булса, шулкадәр түбәнрәк төшкән. Әйе, моннан тыш, бу сәяси һәм гыйшкый интригаларның барысына да мин инде күптән чик куярга карар кылган идем... Ялгышмасам, аңа Ла Порт дигән берәү хезмәт итә шикелле?

— Дөресен генә әйткәндә, мин ул кешене әлеге эштә төп этәргеч дип саныйм,— дип сүз кыстырды кардинал.

— Димәк, минем кебек, сез дә, королева мине алдый, дип уйлыйсыз?

— Минем уемча, галиҗәнап, кабатлап әйтәм: королева король властена каршы заговорга катнаша, ләкин, аның абруена каршы, дип әйтмәдем мин.

— Ә менә мин сезгә әйтәм: ул тегесенә дә һәм монысына да каршы астыртын эш алып бара. Мин әйтәм: королева мине яратмый, ул башка кешене ярата. Мин әйтәм: королева әнә шул явыз Бекингэмны ярата. Нигә сез аны Парижда чагында кулга алмадыгыз?

— Герцогны кулга алыргамы? Король Карл Беренченең беренче министрынмы? Ни сөйлисез, галиҗәнап?! Никадәр шаушу булыр иде! Әгәр сез галиҗәнапның шик-шөбһәләре күпмедер дәрәҗәдә акланса иде — алай булуына мин һаман да шикләнәм әле — ул чагында нинди зур хурлык, нинди коточкыч фаш итәлү булыр иде.

— Әгәр ул берәр сукбай яисә угры бәндә шикелле хәтәр юлда йөргән икән, ул чагында...

Людовик XIII, әйтәсе сүзеннән үзе үк куркып, тыелып калды, Ришелье исә, муенын сузып, аның әйтеп бетермәгән сүзен юкка гына көтте.

— Ул чагында нәрсә?

— Бернәрсә дә түгел, бернәрсә дә түгел...— диде король.— Ул Парижда чагында сез аны күздән ычкындырмагансыздыр бит?

— Ычкындырмадык, галиҗәнап.

— Кайда торды ул?

— Лагарп урамында, житмеш бишенче йортта.

— Кай төштә ул?

— Люксембург сараеннан ерак түгел.

— Сез аны королева белән күрешә алмаган дип уйлыйсызмы?

— Королеваны үз бурычына бик тугрылыклы дип саныйм мин.

— Ләкин алар хат язышалар бит. Королева көне буе шуңа хат язган бит. Герцог! Мин ул хатларны кулга төшерергә тиешмен.

— Галиҗәнап, ул эш...

— Герцог! Ни генә булмасын — мин ул хатларны кулга төшерергә телим.

— Ә шулай да сез галиҗәнапка әйтергә тиешмен мин...

— Инде сез дә миңа хыянәт итәсезме, кардинал әфәнде: һәрвакыт минем теләкләремә каршы киләсез! Әллә сез дә испаннар һәм инглизләр белән, де Шеврез ханым һәм королева белән сүз беркеттегезме?

— Галиҗәнап,— диде кардинал авыр сулап,— мин үземне андый шик-шөбһәләрдән азат дип уйлый идем.

— Кардинал әфәнде, минем әйткәнемне ишеттегезме: мин ул хатларны кулга төшерергә телим.

— Аның бер генә юлы бар...

— Нинди юл?

— Бу миссияне канцлер Сегье әфәндегә тапшыру. Бу эш бөтенләе белән аның вазифасына карый.

— Хәзер үк чакырып китерсеннәр үзен!

— Ул миндәдер. Мин аны үз яныма чакырткан идем, ә Луврга китәргә җыенгач, килсә, мине көтеп торсын дип әйтергә кушкан идем.

— Хәзер үк алып килсеннәр аны.

— Сез галиҗәнапның боерыгы үтәлер, тик...

— Нәрсә «тик»?

— Тик королева, мөгаен, буйсынмас.

— Минем әмерләремә буйсынмасмы?

— Әйе, бу боерыкның сезнең тарафтан бирелүенә ышанып житмәсә — буйсынмас.

— Ярый, алайса, королева шикләнмәсен өчен, мин үзем аңа искәртеп куярмын.

— Галиҗәнап, арагыз өзелү булмасын өчен, минем көчемнән килгәннең барысын да эшләргә тырышканымны онытмассыз дип өметләнәм.

— Әйе, герцог, мин сезнең королевага карата бик мәрхәмәтле булуыгызны беләм... хәтта кирәгеннән артык мәрхәмәтле түгелсез микән. Соңрак без бу мәсьәләгә кайтырбыз әле, искәртеп куям.

— Кайчан теләсәгез дә — ихтыярыгыз, галиҗәнап. Әмма мин сезнең белән Франция королевасы арасындагы дуслык вә

татулык хакына үземне корбан итүне һәркайчан үзем өчен горурлык вә бәхет дип саныйм.

— Бик шәп, кардинал, бик шәп. Тик хәзергә канцлер әфәндене чакырыгыз әле. Мин королева янына керәм.

Шулай дигәч, Людовик XIII, ишекне ачып, үз ягын Анна Австрияленең апартаментлары белән тоташтыра торган коридорга чыгып китте.

Королева үзенең сарай дамалары — де Гито ханым, де Сабле ханым, де Монбазон ханым һәм де Гемене ханымнар белән бергә жыелышып утырганнар иде. Бер почмакка камеристкасы — королева белән бергә Мадридтан килгән донья Эстефания дә урнашып алган иде.

Де Гемене ханым кычкырып китап укый, калганнары, королевадан башкалары, аны бик бирелеп тыңлап утыралар иде. Королева бу эшне, үзе дә тыңлаган булып, уйланып утырырга мөмкинлек булсын өчен генә оештырган иде.

Ә уйлары аның, мәхәббәтенең соңгы чаткыларыннан бераз нурланып торса да, бик хәсрәтле, бик күңелсез иде. Иренең ышанычын югалткан, кардиналның сөю хисләрен кире каккан өчен аның каһәрен күреп яшәгән Анна Австрияле корольнең анасы язмышын күз алдына китерде. Мария Медичи * дә, ул замандагы мемуарларда әйтелгәнчә, имеш, баштарак кардиналны бәхетле итсә дә (ә королева Анна аны бәхетле итәргә теләми иде), соңыннан гомере буе кардиналның каһәрен күреп яшәгән. Анна Австрияле үз күз алдында иң тугрылыклы хезмәтчеләренең, иң ышанычлы дусларының һәм йөрәгенә иң газиз сөйгән кешеләренең югала баруын күреп тора. Зәхмәтле бер кеше кебек, ул үзе кагылган бер нәрсәгә бәхетсезлек китерә иде. Де Шеврез ханым белән де Верне ханымны читкә сөрделәр, хәтта Ла Порт та үзен менә-менә кулга алалар дип торуын хакимәсеннән яшерми иде.

Королева әнә шундый бик күңелсез уйларын уйлап утырганда, ишек ачылып китеп бүлмәгә король килеп керде.

Де Гемене ханым шундук китапны укуыннан туктады, ханымнарның барысы аягүрә бастылар. Һәм бүлмә эчендә кабер тынлыгы урнашты.

Король, исәнләшүне кирәк дип тә санамыйча, королевага таба берничә адым атлады да аның каршына килеп басты.

— Ханым,— диде ул әллә нинди ят бер тавыш белән,— сезнең яныгызга хәзер канцлер әфәнде керер. Мин аңа сезгә нәрсә белгертергә кушкан булсам, ул шуны әйтер сезгә.

Аерылышу, читкә сөрү, хәтта суд хөкеменә бирүләр белән туктаусыз куркытылып торган бичара королева, битләренә иннек-кершән сөрткән булса да, агарынып китте.

---

* Мария Медичи — Француз короле Генрих IV нең хатыны, Людовик XIII нең анасы.

— Бу керүегезнең сәбәбе нәрсә соң? — диде королева, тыелып кала алмыйча.— Сез үзегез миңа әйтә алмаган, канцлер әфәндедән әйттерә торган нәрсә нәрсә ул?

Король, җавап кайтармастан, кырт борылып чыга башлады. Шул минутта ук диярлек дежур торучы гвардия капитаны Гито канцлерның килеп җитүен кереп әйтте.

Канцлер килеп кергәндә, бүлмәдә инде король юк: ул икенче ишектән чыгып киткән иде.

Канцлер уңайсызлануыннан кызарынып, елмаеп килеп керде. Хикәябез дәвамында бу кеше белән тагын очрашуыбыз ихтималы булганлыктан, укучыларыбызга аның белән якынннанрак танышып китү зарар итмәстер кебек.

Канцлер Сегье кызыклы гына бер кеше иде. Мәрьям ана чиркәвенең каноннгы, кайчандыр кардиналның камердинеры булып хезмәт иткән де Рош Ле Маль кардинал хәзрәтләренә де Сегье әфәндене җаны-тәне белән бирелгән бер кеше дип тәкъдим иткән иде. Кардинал бу тәкъдимгә ышанып аны үзенә алды һәм соныннан ник алганына үкенергә туры килмәде.

Де Сегье әфәнде турында әллә нинди имеш-мимешләр дә таралган иде. Шулардан, мәсәлән, менә мондый бер хәлне сөйлиләр.

Яшьлегендә байтак типтереп йөргәннән соң, ул егет чагымдагы азып-тузып йөрүләрем өчен берказдәр вакыт савап кылыйм дип монастырьга китә.

Ләкин әлеге изге йортка кергән чагында бу гөнаһлы бәндә ишекне тиз генә ябып өлгермәгән, күрәсең,— монастырьга качып котылырга теләгән чагында шайтан коткылары аның артыннан иярәп кергән. Шуннан соң шайтан аны туктаусыз котыртып тора башлаган. Көннәрдән беркөнне ул шушы бәласе хакында монастырь назирена сөйләп биргәч, изге ата аңа, андый чакта син, шайтан коткысыннан котылу өчен, чаң бавына ябыш та бөтен көчең белән чаң как, дип киңәш итә. Чаң тавышын ишетү белән, монахлар, туганнарыбызның берсен шайтан котырта икән дип, җыйнаулашып гыйбадәт кылырга керешерләр, янәсе.

Изге атаның бу киңәше канцлер булачак кешегә бик ошап куя. Башка монахлар кылган неэнсез күп догалар ярдәмендә ул үзен шайтан васвасәсеннән саклый башлый. Ләкин шайтан дигәнең бер тотынган эшеннән тиз генә кире чигенми икән. Догалар күбәйгән саен шайтан да тегенең күңеленә коткысын күбрәк сала бара, шулай итеп, чиркәү чаңы, гөнаһлы бәндәнең дәртен басарга теләгәнен белгертеп, көн-төн даңгылдап тора башлый.

Монахларның тын алырга да вакытлары калмый. Көндез бөтен эшләре капеллага менә торган баскычтан туктаусыз йөреп тору булса, төнлә, гадәттәге гыйбадәтләреннән тыш, аларга тагын бер егерме тапкыр урыннарыннан сикереп торып, хөҗрәләренең идәненә йөзтүбән капланырга туры килә.

Шайтан вәсвәсә салуыннан туктагандырмы, әллә монахлар бу эштән тәмам туеп ваз кичкәннәрдерме — ул кадәресе мәгълүм түгел. Тик өч айлап вакыттан соң теге гөнаһлы бәндә яңадан фани дөньяга чыгып, җир йөзендә моңарчы булмаган бик яман бер азгын дигән даның тарата.

Монастырьдан чыккач, ул судья була, парламентта абзасы урынына президент булып ала, кардинал ягына күчә (моның анысы аның искиткеч бер зирәклеген күрсәтә), канцлер итеп куела, кардинал хәзрәтләре кулында корольнең анасына һәм Анна Австриялегә каршы астыртын көрәштә турылыклы бер корал булып хезмәт итә; Шаленың суд эше дәвамында судьяларны аңа каршы котыртып тора, бөек эконом Лафемның бөтен эшендә булышлык итә һәм шул рәвешчә, лаеклы рәвештә, кардиналның ышанычын тулысынча казангач, менә хәзер королева янына керергә сәбәп булган йомышны үз өстенә ала.

Ул килеп кергәндә королева әле һаман аягүрә басып тора иде, аны күргәч, креслосына утырды да дамаларына мендәр һәм пуфларга утырырга дип ымлап боерык бирде. Аннары горур бер төс белән канцлерга таба борылды.

— Сезгә ни кирәк, әфәндем? Бирегә нинди йомыш белән кердегез? — дип сорады Анна Австриялe.

— Сезне бик тирән ихтирам итүемә дә карамастан, корольнең кушуы буенча, мин сезнең кәгазьләрегезгә җентекләп тентү ясарга мәҗбүрмен.

— Ничек ул алай, әфәндем?! — диде королева.— Мине тентемәкче буласызмы?.. Мине?.. Нинди коточкыч түбәнлек бу!

— Гафу итегез, олуг ханым, әмма бу минутта мин король кулындагы бер корал гынамын. Король галиҗәнаплары әле хәзер генә биредә булды түгелме? Сездән минем керүемә әзер булып торуыгызны үтенмәдеме?

— Эзләгез, актарыгыз, әфәндем. Мин җинаять кылганмындыр, күрәсең... Эстефания, минем өстәл һәм бюроларымның ачкычларын бирегез.

Канцлер, королеваның көндез язган бик мөһим хатын өстәл тартмасында сакламаганлыгын белсә дә, тартмаларда актарынган булды.

Өстәл тартмаларын бер егерме тапкыр ачып япканнан соң, канцлерга, беркадәр кыюсызлыгын җиңеп, барыбер бу эштәге соңгы чарага керешергә, ягъни королеваны тентергә туры килде.

Ул Анна Австриялегә таба борылды да аптыраштa калган, бик уңайсызланган бер тавыш белән:

— Хәзер миңа тентүнең төп өлешенә керешергә туры килә,— диде.

Королева, канцлерның ниятен аңламыйчамы, әллә аңларга теләмичәме:

— Нинди төп өлешенә? — дип сорады.

— Бүген көндез королеваның хат язганлыгын король хәз-

рәтләре белә. Ул хатның әле тиешле кешесенә җибәрелмәгәнлеге дә галиҗәнапка мәгълүм. Әлеге хат сезнең өстәлегездә дә, бюрогызда да юк. Хәлбуки, ул каядыр яшерелгән.

Анна Австрияле туп-туры басты да канцлерга усал бер караш ташлап:

— Королевагызны капшарга җөрьәт итмәкче буласызмы әллә? — диде.

— Мин корольнең турылыклы хезмәтчесе, ул галиҗәнап ни кушса — мин шуны үтим.

— Әйе, анысы хак сүз! — диде Анна Австрияле.— Кардинал җәнапларының шымчылары да аңа турылыклы хезмәт күрсәткәннәр. Мин бүген чыннан да хат язган идем. Ул хат менә монда,— дип, королева гүзәл кулын түшенә куйды.

— Алайса ул хатны миңа бирегез, олуг ханым,— диде канцлер.

— Мин аны корольнең үзенә генә бирәм,— диде Анна.

— Әгәр король ул хатны сез олуг ханымнан үзе алырга теләсә, сездән аны үзе сораган булыр иде. Шуңа күрә кабатлап әйтәм: миңа ул сездән әлеге хатны таләп итәргә кушты, әгәр дә ки сез баш тартсагыз...

— Әйтегез, әйтегез!

— Ул миңа аны сездән алырга кушты.

— Ничек? Нәрсә димәкче буласыз сез?

— Минем вәкаләтем бик зур, ул кәгазьләрне табу өчен миңа хәтта сез олуг ханымны шәхсән тентергә дә рөхсәт бирелгән димәкче булам.

— Коточкыч хәл! — дип кычкырып җибәрде королева.

— Шуңа күрә, ханым, карышмавыгызны сорыйм.

— Сезнең кыланышыгыз коточкыч тупас, аңлыйсызмы сез шуны, әфәндем?

— Король шулай боерды, олуг ханым. Мине гафу итегез.

— Минем мондый хурлыкка түзәр хәлем юк! Юк, юк, үлгәнем яхшы! — дип кычкырды королева, аның йөрәгендәге Испания һәм Австрия корольләренең горур каны кызышып, кайнап китте.

Канцлер бөгелеп баш иде, аннары үзенә тапшырылган бурычны үтәүдән бер адым да чигәргә нияте юклыгын сиздереп, төрмәдәге палач үз эшен башкарган кебек, Анна Австриялегә якынлашты, шул мәлдә үк ачу-гарьлектән королеваның күз яшьләре атылып чыкты.

Әйткәнебезчә, королева бик чибәр хатын иде. Шуңа күрә кемгә дә булса мондый йомыш кушу шактый хәтәр нәрсә, әмма король, герцог Бекингэмга карата йөрәгендә кайнаган көнчелек тойгыларына бирелеп, башкалардан көнләшми башлаган иде инде.

Бу минутта канцлер Сегье, мөгаен, күзе белән теге чаңның бавын эзләгәндер, аны таба алмагач, ул кулын королева үзе әйткән, әлеге хат яшерелгән төшкә сузды.

Анна Австрияле бер адым артка чикте, үләр дәрәҗәгә житешеп агарынып китте. Егылып китмәс өчен сул кулы белән артында торган өстәлгә таянды, ә уң белән изүе эченнән хатны алды да канцлерга сузды.

— Мәгез хатны, әфәндем! — диде королева дулкынланудан тавышы буыла-буыла.— Мәгез, алыгыз да жирәнгеч кыяфәтегезне күрүдән коткарыгыз мине.

Канцлер дулкынлануыннан калтырый-калтырый хатны алды да, жиргә чаклы бөгелеп баш игәч, чыгып китте.

Аның артыннан ишек ябылу белән, королева, һушыннан язып, янындагы ханымнарның кулына ауды.

Канцлер хатны, эченә күз салмыйча, корольгә кертеп бирде. Хатны алган чакта корольнең кулы калтырангалап куйды. Хатның адресын эзли башлады — адресы юк иде — чырае көл төсле агарынып китте, ашыкмыйча гына хатны ачып, беренче сүзеннән үк аның испан короленә язылган икәнен күргәч, тиз-тиз генә укып чыкты.

Бу хат кардиналга һөжүм итүнең тулы бер планы иде. Королева бу хатында Ришельеның Австриядәге корольнең йортын даими рәвештә кимсетү политикасына гарьләнгән абыйсы белән Австрия короленә «Франциягә каршы сугыш башлыйбыз» дип куркытырга һәм кардиналның эштән алынуын ике арада тынычлык саклауның шарты итеп куярга тәкъдим иткән иде. Мәхәббәт турында хатта бер сүз дә әйтелмәгән иде.

Король, шундук чырае яктырып китеп, кардиналның хәзер сарайдамы икәнлеген белергә кеше жибәрде. Кардинал хәзрәтләре үзенең кабинетында, корольнең боерыкларын көтеп утыра, дип кереп әйттеләр.

Король шундук кардинал янына китте.

— Беләсезме, герцог, мин түгел, бәлки сез хаклы булып чыктыгыз бит,— диде король.— Бөтен интрига чыннан да сәяси хосусиятле, бу хатта мәхәббәт турында бер сүз дә әйтелмәгән. Аның каруы хатта сезнең хакта бик күп әйтелгән.

Кардинал хатны алып бик зур игътибар белән укып чыкты. Укып бетергәч, тагын бер кат укыды.

— Менә бит, галиҗәнап, дошманнарымның ни дәрәҗәгә житүләрен үзегез күреп торасыз,— диде ул,— әгәр сез мине эшемнән алмасагыз, сезне ике жирдән сугыш ачабыз дип куркыталар. Сезнең урында булсам, галиҗәнап, мин, ихластыр, аларның шулкадәр тырышуларына каршы тора алмас идем, бирешер идем. Ә мин исә, үз тарафымнан, эштән китүемә бик бәхетле булыр идем.

— Ни сөйлисез, герцог!

— Шуны әйтәм, галиҗәнап, мондый чамасыз киеренке көрәштә һәм иксез-чиксез эштә минем сәламәтлегем какшый. Ларошельне камап торуның авырлыгын күтәрә алмам, ахры, шуна күрә анда де Конде әфәндене билгеләсәгез яхшырак булыр дим, чөнки сугышны алып бару турыдан-туры аның эше

бит, минем эш түгел. Мин — дингә хезмәт итүче кеше, тик һәвәслегем булмаган эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр итеп, омтылган эшемә бирелергә мөмкинлек калдырмыйлар дим. Шулай итсәгез, гаилә тормышыгызда бәхетле яшәрсез һәм, һичшиксез, чит илләрдә дә сезнең даныгыз ныгый төшәр.

— Борчылмагыз, герцог. Мин барысын да аңлыйм. Бу хатта исемнәре аталган кешеләр барысы да тиешле җәзаларын алырлар, королева да җәзасыз калмас,— диде король бу сүзгә каршы.

— Ах, ни сөйлисез, галиҗәнап! Королевага минем аркада берәр төрле кимчелек килүдән берүк ходай саклый күрсен! Ул мине һәрвакыт үзенең дошманы дип санады, гәрчә сез, галиҗәнап, аны хәтта сезнең алда да бик тырышып яклаганымны үзегез дә раслый аласыз. О, әгәр дә ул сез галиҗәнапка хыянәт итеп абруегызга тап төшерсә икән, ул чагында инде башка хәл булыр иде, мин үзем беренче булып әйтер идем: «Гаеп кылучыга бернинди рәхим-шәфкать юк!» — дияр идем. Бәхеткә каршы, ул хакта сүз дә булуы мөмкин түгел, моның шулай икәнлегенә сез, галиҗәнап, үзегез янә бер тапкыр ышандыгыз.

— Анысы дөрес, кардинал әфәнде,— диде король.— Сез һәрвакыттагыча хаклы булып чыктыгыз. Әмма шулай да королевага минем ачуым бар.

— Галиҗәнап, сез үзегез аның каршында гаепле бит. Киресенчә, ул үзе сезгә ачу тотса, бик табигый булыр иде. Сез, галиҗәнап, аңа карата артык кырыс мөгамәлә күрсәттегез.

— Кырыслыгым аркасында нинди генә куркынычлыкларга тарсам да, үз дошманнарыма да, сезнең дошманнарга да, нинди югары дәрәҗәле булуларына карамастан, мин һәрвакыт шундый мөгамәлә күрсәтәчәкмен.

— Королева сезгә дошман түгел бит, миңа дошман, галиҗәнап. Киресенчә, ул сезнең турылыклы, карусыз, бик әйбәт хатыныгыз. Сез галиҗәнап алдында аны якларга рөхсәт итегез миңа

— Алайса беренче булып ул чигенсен, беренче адымны ул ясасын.

— Киресенчә, галиҗәнап, сез яхшы үрнәк күрсәтегез. Королевага карата шик тотып сез үзегез гаепле булдыгыз бит.

— Беренче адымны мин ясарга тиешмени?! Һичкайчан булмас! — диде король.

— Галиҗәнап, бик үтенәм сездән!

— Аннары тагы, уңайлы сылтавын ничек табасың аның?

— Аның күңеленә хуш килердәй берәр нәрсә эшләгез.

— Я, нәрсә ул?

— Бал ясагыз. Королеваның танцы яратканын беләсез бит. Ихластыр, шундый илтифат күрсәтсәгез, түзмәячәк, эчуы язылып бетәчәк аның.

— Кардинал әфәнде, сез минем андый күңел ачуларны яратмаганымны беләсез бит инде.

— Сезнең андый кәеф-сафа кылуларны өнәмәгәнлегегезне белгәч, ул сезгә бигрәк тә рәхмәт укыячак. Өстәвенә, күптән түгел генә аның туган көненә сез бүләк иткән теге асылташларны тагарга да җай чыгачак — королеваның аны кеше арасына тагып чыкканы юк бит әле.

Королева корольне бик аз борчыган бер җинаятьтә гаепле булса да, аны иң нык хафага салган мәсьәләдә бөтенләй гаепсез булып чыкты. Король, әнә шул уйдан кәефе килеп, аның белән татулашырга әзер булган бер хәлдә:

— Карарбыз, кардинал әфәнде, карарбыз,— диде.— Шулай да, ант әгәр, артык мәрхәмәтле кеше сез.

— Галиҗәнап,— диде кардинал бу сүзгә каршы,— усаллыкны министрларга калдырыгыз. Мәрхәмәт күрсәтү ул — корольләр сыйфаты, мәрхәмәт кылсагыз, моның файдага гына икәнен күрерсез.

Шуннан соң кардинал, сәгать унбер сукканын ишеткәч, баш иеп, китәргә рөхсәт сорады да, саубуллашкач, корольдән королева белән татулашуын үтенеп китеп барды.

Теге хатны талап алганнан соң, Анна Австрияле корольдән әр-шелтә ишетермен дип көткән иде, шуңа күрә иртәгесе көнне ул корольнең татулашырга ниятләвен сизеп бик гаҗәпкә калды. Баштарак ул аның мондый ниятен кире кагардай булып тора иде: аны хатын-кыз да һәм королева буларак та шул хәтле кимсеттеләр — мондый гарьлекне тиз генә онытырлык түгел иде. Әмма сарай дамаларының үгетен тыңлап, ахыр чиктә ул әлеге хәлне оныта башлаганга салышты. Король, бу үзгәрештән файдаланып, королевага шушы арада зур бал җыярга ниятләвен әйтте.

Бичара Анна Австрияле өчен бал дигәнебез шундый тансык бер нәрсә иде — бу хәбәрне ишеткәч, кардиналның үс расланганча, королеваның йөрәгеннән үк булмаса да, чыраенннан үпкә-гарьлегенең соңгы эзләре дә юкка чыкты. Королева бу бәйрәмнең кайсы көнне булачагын сорады, тик король, бу хакта кардинал белән сөйләшәсе бар әле, дип кенә җавап бирде.

Чыннан да, король бу бәйрәмне кайчан ясыйбыз дип кардиналдан көн саен сорады, кардинал исә, көн саен берәр төрле сылтау табып, көнен үзе әйтүдән баш тарта килде.

Шул рәвешчә ун көн узып китте.

Без сөйләгән хәлләрдән соң сигезенче көнне кардинал Лондоннан бер хат алды. Хатта болай дип кенә язылган иде:

«Мин тегене кулга төшердем. Акчам житмәү сәбәпле, Лондоннан чыгып китә алмыйм. Миңа биш йөз пистоль акча җибәрегез, акчаны алгач, дүрт-биш көннән Парижда булырмын».

Кардинал шушы хатны алган көнне король әлеге соравы белән аңа мөрәҗәгать итте.

Ришелье бармаклары белән санап карады да күңеленнән болай дип уйланды:

«Акча алганнан соң дүрт-биш көннән кайтып җитәм дип яза. Акча Лондонга барып җиткәнче биш көн уза, үзе монда кайтып җиткәнче биш көн. Димәк, җәмгысы — ун көн. Җилнең каршыга исүен, андый-мондый көтелмәгән хәлләр килеп чыгуын һәм авырып китүләрне дә искә алырга кирәк. Әйтик, унике көн...»

— Я, герцог, исәпләп карадыгызмы? — диде король.

— Әйе, галиҗәнап. Бүген безнең егерменче сентябрь. Шәһәр башлыклары өченче октябрьда бәйрәм ясыйлар. Хәлләр бик җайлы килеп тора. Берәү дә сезне королевага юл куйды дип уйламаячак.

Шулай дигәч, кардинал беравык тынып торды да өстәп куйды:

— Аннары, бәйрәм алдыннан королевага шуны да әйтергә онытмагыз әле: асылташлар сиңа килешә микән, шуны күрәсем килә, дип әйтегез.

## *XVII*

## *БОНАСЬЕЛАР*

Король белән сөйләшкәндә кардинал асылташларны инде икенче тапкыр телгә алды. Аның һаман шулай бер үк нәрсәне кабатлавы Людовик XIII не гаҗәпкә калдырды, һәм моның астында берәр төрле сер булырга тиеш дип уйлады король.

Хәзерге заман полициясе камиллегенә җитмәсә дә, бер дигән полициясе булган кардиналның король хәзрәтләренең үзеннән дә күбрәк белүенә ул күңеленнән рәнҗеп тә куйгалый иде. Бу юлы инде король, Анна Австрияле белән сөйләшү мин белмәгән бер-бер хәлне ачарга тиеш, дип уйлады. Аннары ул, кардинал хәзрәтләренә мәгълүм яки мәгълүм булмаган ул серләрне белгәннән соң, аны яңадан күрергә ниятләде. Кардинал ул серләрне белсә-белмәсә дә, министры каршында корольнең дәрәҗәсе үсеп китәргә тиеш иде.

Людовик XIII королева янына керде һәм гадәтенчә сүзне королеваның ышанычлы якын кешеләренә карата янаудан башлады. Анна Австрияле башын иеп кенә тыңлап торды, сүзенең бер азагы булыр дип, корольнең эчен бушатып бетергәнен көтте. Әмма король моның белән генә чикләнеп калырга теләми иде. Ул ызгышырга тели, кызып киткәч, бер-бер хәл ачылырлык сүз чыкмасмы дип өметләнә иде. Ул кардиналның ниндидер бер яшерен уе бар, кардинал — көтелмәгән коточкыч нәрсәләр оештыруның тиңдәшсез бер остасы — аңа әнә шундый берәр хәл эшләргә җыена дип ышана иде. Корольнең туктаусыз гаеп ташлап торуы, ниһаять, теләгән максатына ирештерде.

— Галиҗәнап, нигә сез күңелегездә булганны туп-туры әйтмисез? — диде Анна Австрияле, корольнең ишарә-кинаяләр бе-

лән генә гаепләвенә түземе бетеп.— Нәрсә эшләгәнмен соң мин? Нинди җинаять кылганмын? Минем абыема язган хатым аркасында гына галиҗәнапның шундый гауга чыгаруы мөмкин түгел.

Король мондый туры сорауга ничек итеп җавап бирергә кирәклеген тиз генә уйлап җиткерә алмады. Бәйрәм алдыннан гына әйтәсе сүзне хәзер үк әйтергә кирәк дип уйлады.

— Ханым,— дип сүзен башлады ул җитди бер төс белән,— *шушы арада ратушада бал оештырылачак.* Безнең шанлы кала башлыкларын ихтирам итү йөзеннән, сезгә ул балга бәйрәм күлмәге киеп, һәм, әлбәттә, туган көнегезгә мин бүләк иткән асылташларны да тагып барырга кирәк булыр дип саныйм. Минем җавабым шул.

Бик яман иде бу җавапның мәгънәсе. Анна Австрияле: король барысын да белә икән, кардинал кушуы буенча гына ул атна буена берни сиздерми йөргән икән, дип уйлады. Хәер, мондый астыртынлык корольнең табигатенә хас нәрсә иде. Королева ашлаган киндер төсле агарынып китте, шушы минутта балавыздан ясалган сыман тоелган искиткеч матур кулы белән ул кечкенә өстәленә таянды. Коты алынган күзләре белән корольгә караган килеш ләм-мим сүз дәшмәде.

— Ишетәсезме, ханым? — диде король, королеваның ни өчен каушап калуының сәбәбен төшенеп җитмәсә дә, аның бу хәленнән үзенчә бер ләззәт тапты.— Ишетәсезме?

— Ишетәм, әфәндем,— дип, иренен кыймылдатып кына куйды королева.

— Әлеге балда булырсызмы?

— Әйе.

— Асылташларны тагарсызмы?

— Әйе.

Королеваның йөзе тагы да агара төште. Король моны күреп торды һәм характерындагы иң ямьсез сыйфатларның берсе булган салкын рәхимсезлеге белән королеваның хафалануыннан ләззәтләнеп:

— Димәк, сөйләшенде! Минем сезгә әйтәсе сүзем шул иде,— диде.

— Бал кайсы көнгә билгеләнгән соң? — дип сорады Анна Австрияле.

Людовик XIII бу сорауга җавап бирмәскә кирәклеген төшенеп алды: королеваның тавышы үлеп барган бер кеше тавышы сыман иде.

— Шушы арада, ханым,— диде король.— Көне исемдә түгел, кардиналдан сорарга булыр.

— Димәк, сезгә кардинал хәзрәтләре бал оештырырга киңәш иткән? — диде королева.

— Әйе, ханым. Нигә алай дип сорыйсыз? — диде король гаҗәпләнеп.

— Асылташларны тактыру хакында да ул киңәш иттеме?

— Ни дип әйтергә сезгә...

— Ул әйткән, галиҗәнап, ул!

— Мин булсам да, ул булса да — барыбер түгелмени? Минем ул үтенечемнән җинаять күрмисездер бит?

— Юк, әфәндем.

— Димәк, балда буласыз?

— Әйе.

— Бик шәп,— диде король, ишеккә таба атлап.— Вәгъдәгездә торырсыз дип ышанам.

Королева, әдәп йөзеннән бигрәк, тез буыннары тотмаганга, реверанс ясап алды.

Король бик канәгать булып чыгып китте.

— Беттем! — дип пышылдады королева.— Беттем! Кардинал бөтенесен белә. Корольне миңа каршы ул котырта. Хәзергә әле ул берни белми, әмма озакламый беләчәк. Беттем мин! Ай аллам! Ай аллам!..

Королева идәнгә тезләнде дә, калтыранган куллары белән битен каплап, гыйбадәт кылырга кереште.

Хәле аның чыннан да яман иде. Герцог Бекингэм Лондонга кайтып китте, де Шеврез ханым — Турда. Үзе артыннан монархыга караганда ныграк күзәтә башлаганнарын белгәнлектән, королева сарай дамаларыннан берсенең аңа хыянәт иткәнлеген сизенә, ләкин кайсы икәнен тәгаен белми иде. Ла Портның Луврдан чыгып йөрү мөмкинлеге юк; королева дөньяда беркемгә дә ышанып серен ача алмый иде.

Башына нинди зур бәла килгәнлеген, дөньяда үзенең япаялгыз булуын аермачык итеп күз алдына китерү белән ул түзмәде — үкереп елап җибәрде.

Шунда кинәт аны кызганган, кайгысын уртаклашкан сыман нәфис бер тавыш ишетелде.

— Олуг ханымга минем берәр ярдәмем кирәк булмасмы? — диде бу тавыш.

Королева ялт кына борылып карады; мондый тавышны ялгыш ишетү мөмкин түгел: бары тик аны якын иткән кеше генә шундый итеп эндәшә ала иде.

Һәм, чыннан да, королева бүлмәсенә керә торган ишекләрнең берсе төбендә чибәр генә Бонасье ханым басып тора иде. Ул күрше бүлмәдә королеваның күлмәкләрен һәм эчке киемнәрен җыештырган һәм, король килеп кергәч, чыгып китә алмый калган. Шулай итеп, Бонасье ханым аларның сөйләшкәнен ишетеп торган иде.

Королева, бүлмәсендә кеше барлыгын күрү белән, кычкырып җибәрде. Курку-каушавыннан үзе янына Ла Порт урнаштырган яшь ханымны тиз генә таный да алмады.

— О, курыкмагыз, олуг ханым,— диде яшь хатын, хакимәсенең кайгы-хәсрәт эчендә булуын күрү белән ул да кулларын уа-уа еларга керешкән иде.— Сез олуг ханымга мин җаным-тәнем белән бирелгәнмен, мин сездән никадәр ерак булсам да,

дәрәҗәм никадәр түбән булса да, сез олуг ханымны бу бәлагездән ничек итеп коткару әмәлен уйлап таптым шикелле.

— Сез? Ай тәңрем! Сез? —дип кычкырып эндәште королева.— Күземә туры карагыз әле. Минем бөтен тирә-ягымны хыянәтчеләр чолгап алган. Сезгә ышанып серемне тапшыра аламмы?

— Олуг ханым! — диде яшь хатын идәнгә тезләнеп.— Җаным белән ант итәм: сез олуг ханым өчен үләргә дә әзермен мин!

Инәлеп әйтелгән бу сүзләр йөрәк түреннән чыкканга ихлас булуына бернинди шик калдырмады.

— Әйе,— диде Бонасье ханым.— Әйе, биредә хыянәтчеләр бар. Ләкин бер ходаем белән ант итәм: сез олуг ханымга минем кебек тугрылыклы беркем дә юк. Король әйткән теге асылташларны сез герцог Бекингэмга биргән идегез бит, шулаймы? Ул асылташлар герцог алып киткән алсу агач тартмага салып куелган идеме? Әллә мин ялгышаммы, әллә кирәкмәс сүз сөйлимме?

— Ай аллам, ай аллам! — дип пышылдады королева, куркуыннан теше тешкә бәрелде.

— Менә шул: ул асылташларны кире кайтарырга кирәк,— диде Бонасье ханым.

— Әйе, әлбәттә, кайтарырга кирәк. Тик ничек кайтарырга соң аны? — диде королева инәлеп.

— Герцог янына берәр кеше җибәрергә кирәк.

— Кемне җибәрергә? Кемне? Кемгә ышанырга мөмкин моны?

— Олуг ханым, ышаныгыз миңа. Күрсәтегез миңа андый хөрмәтне, королевам, җибәрер кешесен үзем табармын.

— Ләкин хат язарга кирәк булачак бит!..

— Шунсыз булмый. Сез олуг ханымның үз кулы белән язылган ике-өч кенә сүз һәм сезнең шәхси печәтегез.

— Ул ике-өч сүз — үз-үземә хөкем чыгару, аерылу, сөрелү дигән сүз бит.

— Эшәке булса да кулына эләксә — шулай. Әмма сез ышаныгыз миңа: ул хат тиешле кешесенә генә тапшырылыр.

— Йа хода! Мин бит сезгә үземнең тормышымны, намусымны, абруйлы намемне ышанып тапшырырга тиеш булам.

— Әйе, ханым, шулай тиеш буласыз. Шуннан соң мин сезне бәлагездән коткарачакмын.

— Ничек коткарасыз соң? Һич югы, әйтеп күрсәтегез миңа.

— Моннан ике-өч көн элек минем иремне төрмәдән чыгардылар. Мин әле аның белән күрешергә дә өлгермәдем. Яхшы күңелле, гади бер кеше ул, нәфрәт дигән нәрсәне дә, мәхәббәт дигәнне дә белми. Мин ни теләсәм — шуны эшли. Юлга чыкканда үзенең нәрсә алып барганын белмәячәк, сез олуг ханымның хатын, сезнең исемнән икәнлеген белмичә, күрсәтелгән адресына илтеп тапшырачак.

Королева, шатлыгыннан тетрәнеп, яшь ханымның ике кулын берьюлы тотып кысты да, аның күңел төбендәниләр барлыгын белергә теләгәндәй, күзләренә текәлеп карады. Бу яшь ханымның матур күзләрендә фәкать ихлас эчкерсезлек кенә күреп, аны яратып битеннән үпте.

— Эшләче шуны! — диде.— Эшләсәң, син минем тормышымны, абруемны саклап калачаксың!

— Һай, сезгә күрсәтәсе ярдәмемне ул кадәр арттырып әйтмәгез! Миңа берни дә коткарасы юк: сез олуг ханым — бары тик астыртын рәвештә мәкер коручы әшәке бәндәләрнең бер корбаны гына.

— Анысы хак, балам, сүзең дөрес,— диде королева.

— Алайса, хатны язып бирегез, олуг ханым. Вакыт көтми.

Королева кара, кәгазь, каләмнәр куелган кечкенә өстәл янына йөгереп килде: тиз-тиз генә ике юл язды да хатны, үз печәтен басып ябыштырганнан соң, Бонасье ханымга сузды.

— Әй, бик кирәк нәрсәне оныткачбыз бит,— диде королева.

— Нинди нәрсәне?

— Акча.

Бонасье ханым кызарынып китте.

— Әйе, дөрес анысы. Турысын әйтим, минем ирем...— дип сөйләнеп куйды.

— Иреңнең акчасы юкмы? Шулай дип әйтмәкче идеңме?

— Юк, аның акчасы бар. Тик бик саран кеше ул — зур кимчелеге ул аның. Ә сез, олуг ханым, борчылмагыз, без аның чарасын табарбыз...

— Минем дә акчам юк шул...— дип сөйләнде королева. (Де Моттвиль ханымның мемуарларын укыган кешеләр королеваның мондый җавабына гаҗәпләнмәсләр.) — Туктагыз әле...

Королева Анна үзенең шкатулкасы янына килде.

— Менә шушы йөзекне ал,— диде ул.— Моның бәһасе бик кыйммәт диләр. Миңа моны абыем — Испания короле бүләк иткән иде. Бу минем шәхсән үземнеке, мин аны теләсә ни эшләтә алам. Бу йөзекне алып акчага әйләндер дә, ирең юлга чыгып китсен.

— Теләгегез бер сәгатьтән үтәлер.

Королева сүзләре көчкә-көчкә генә ишетелерлек итеп пышылдап әйтте:

— Адресын күрәсең. Милорд герцог Бекингэмга, Лондон, диелгән.

— Бу хат аның үз кулына тапшырылыр.

— Эчкерсез балакай! — дип куйды королева.

Бонасье ханым королеваның кулын үпте дә, хатны изү эченә яшергәч, кош шикелле очып кына чыгып та китте.

Ун минуттан инде ул өенә дә кайтып җитте. Королевага әйткәненчә, аның чыннан да ирен төрмәдән чыкканнан бирле күргәне юк иде әле. Ул иренең кардиналга карашы үзгәргәнен дә белми иде, бу үзгәреш исә Бонасье әфәнденең бик якын

дустына әйләнгән граф Рошфорның ике-өч тапкыр килеп китүеннән соң туган иде.

Бонасье әфәнденең хатынын урлау бернинди яман максат белән эшләнмәгән, бәлки политик саклык чарасы гына икәнлегенә граф аны бик ансат ышандырды.

Бонасье ханым кайтып кергәндә ире өйдә үзе генә иде: ул бичара йортта көч-хәл белән тәртип урнаштырып ята иде. Бөтен мебель диярлек ватылып-җимерелеп беткән, шкафлар да буш диярлек: гадел хөкем ияләре теге Соломон патша әйткән, үз артларыннан эз калдырмый торган өч нәрсә исәбенә керми иде, күрәсең. Асрау кыз исә хуҗаны кулга алу белән үк йорттан чыгып качкан иде. Бичара кызның шулкадәр коты алынган — ул Парижидан туп-туры туган җире Бургундиягә кайтып киткән иде.

Мөхтәрәм галантерейчы өенә кайтып җитү белән үк үзенең исән-аман икәнлеген хатынына хәбәр иттерде, хатыны исә аны котылуы белән тәбрикләп, эшемнән бушаган ара булу белән үк сине кайтып күрермен дип әйттерде.

Ләкин буш ара чыкканын биш көн буе көтәргә туры килде,— башка вакыт булса, Бонасье әфәндегә бу, әлбәттә, бик озак ара булып тоелыр иде. Әмма кардинал белән булган әңгәмәсе һәм граф Рошфорның килгәләп китүе Бонасье әфәндегә уйланыр өчен бик күп азык биргән, уйланып яшәгәндә исә, белгәнебезчә, вакытның узганы сизелми дә кала.

Өстәвенә Бонасьеның уйлары андый-мондый гына да түгел,— аллы-гөлле иде. Рошфор аны дустым дип, кадерле Бонасье дип атады һәм әледән-әле: кардинал сезгә карата иң яхшы фикердә, дип тукый торды. Галантерейчы инде үзен баеп барган, кадер-хөрмәткә тиенгән бер кеше итеп күз алдына китерде.

Бу вакыт эчендә Бонасье ханым да бик күп уйланды, тик, дөресен әйтик, аның уйларында байлык һәм дан-дәрәҗә дигән нәрсәләр юк иде. Ирек-ихтыярыннан тыш, аның күңеле, кайта-кайта, үзен ялкынланып сөйгән теге батыр, чибәр егетне уйлый иде. Бонасье әфәндегә унсигез яшендә иргә чыгып, аның дуслары мохитында гына — үз дәрәҗәсенә караганда бөегрәк җанлы бу яшь ханымның күңелендә нинди дә булса тойгы уятырга сәләтле булмаган кешеләр арасында — яшәгәндә Бонасье ханым арзанлы тойгыларга алданып-бирелеп китмәгән иде. Әмма ул елларда дворянлык дәрәҗәсенең башка чорлардагыга караганда да гади кала кешесенә тәэсире бик көчле иде, ә д'Артаньян, белгәнебезчә, дворян егете иде. Аннан тыш, егет гвардияче киеме кигән, бу форма исә, мушкетер киеменнән кала, хатын-кызга бик ошый иде. Әйткәнебезчә, егет яшь, чибәр, булдыклы-житез иде, мәхәббәт турында ул гашыйк булган, сөю һәм сөелүгә сусаган бер кеше кебек сөйли, егерме өч яшьлек яшь бер хатынның башын әйләндерер өчен әнә шулар

да бик житкән. Бонасье ханым исә гомеренең нәкъ шундый бәхетле бер чорын кичерә иде.

Шул сәбәпле, ир белән хатын күрешкән чакларында атна буе бер-берен күрмәгән булсалар да,— бу атна эчендә аларның башларыннан шактый хәлләр кичте бит,— һәркайсы үз уена чумган иде. Шулай да Бонасье әфәнде, чын-ихлас сөенүен белгертеп, хатынын кочагын җәеп каршы алды.

Бонасье ханым аңа маңгаен үптерде.

— Сөйләшәсе сүзем бар,— диде хатын.

— Нинди сүз? — диде Бонасье гаҗәпләнеп.

— Бик мөһим бер нәрсә әйтәсем бар,— дип сүзенә кереште Бонасье ханым.

— Ярый, хәер, минем дә сезгә берничә шактый җитди соравым бар,— диде Бонасье, хатынын сүзеннән бүлдереп.— Рәхим итеп әйтегез әле: ни өчен урладылар сезне?

— Хәзер сүз ул турыда түгел әле,— дип җавап кайтарды Бонасье ханым.

— Ни турында соң? Минем төрмәдә утырып чыгуым турындамы әллә?

— Сезне төрмәгә алып китүләрен шул көнне үк белдем мин. Ләкин сез бит бернинди дә җинаять эшләмәгәнсез, бернинди интригага да катнашмагансыз, аннары үзегезне яки башка берәүне фаш итәрлек нәрсәләр дә белмисез,— шулай булгач, мин ул хәлгә әллә ни мәгънә бирмәдем, гади бер хәл итеп кенә карадым.

— Сезгә, ханым, алай сөйләве ансат! — диде Бонасье, хатынының илтифатсызлык күрсәтүенә кәефе китеп.— Ә менә минем Бастилиядә бер тәүлек утырып чыгуым сезгә мәгълүм микән соң?

— Тәүлек кенә бик тиз уза ул. Сезнең төрмәдә ничек утыруыгыз турында сөйләшмәбез бит инде. Мин нинди йомыш белән кайтсам, шул хакта сөйләшик.

— Ничек инде ул «нинди йомыш белән кайтсам»? Сез атна буе күрешмәгән ирегезне күрер өчен кайтмадыгызмыни? — диде галантерейчы, хатынының әлеге сүзенә бик яман үртәлеп.

— Әлбәттә, иң элек шуның өчен кайттым. Аннары башкасы өчен дә.

— Сөйләгез.

— Бик мөһим бер эш бу, ихтимал, киләчәктәге бөтен язмышыбыз шуңа бәйледер.

— Мин сезне күрми яшәгән арада, Бонасье ханым, безнең хәлләр бик нык үзгәрде, шуңа күрә берничә айдан күп кеше безнең хәлдән көнләшә башласа, мин бер дә гаҗәпләнмәм.

— Әйе, шулай, мин әйтәчәк нәрсәләрне сез җиренә җиткереп башкарып чыга алсагыз — бигрәк тә.

— Мин?

— Әйе, сез. Бик яхшы изге бер эш башкарырга кирәк. Шунда берьюлы бик күп акча да эшләп булачак.

Бонасье ханым акча турында әйтеп иренең йомшак кылына кагыласын белә иде.

Әмма теләсә нинди кеше, галантерейчы да, кардинал Ришелье белән бер ун минут сөйләшкәннән соң, бөтенләй икенчегә әйләнә иде.

— Акчасы күпме соң? — дип сорады Бонасье, аскы иренен очлайтып.

— Күп.

— Чама белән күпме?

— Бәлки, мең пистоль булыр.

— Димәк, сезнең миңа әйтәсе йомышыгыз бик мөһим?

— Әйе.

— Аның өчен ниләр эшләргә кирәк инде?

— Сез хәзер үк юлга чыгасыз. Мин сезгә бер хат бирәм, сез аны күз карасы кебек саклап, тиешле кешесенең кулына тапшырасыз.

— Кая барам инде мин?

— Лондонга.

— Мин? Лондонга? Шаяртасыз мәллә?! Лондонда минем бернинди хаҗәтем калмаган!

— Сезнең Лондонга баруыгыз башка кешеләр өчен кирәк.

— Кемнәр ул башка кешеләр? Мин сезне кисәтеп куям: моннан ары мин сукыр рәвештә берни дә эшләмәячәкмен, нинди куркыныч эшкә баруымны гына түгел, кемнәр өчен баруымны да белергә телим.

— Сезне бик зур бер кеше йомыш белән җибәрә һәм бик зур бер кеше сезне анда көтеп тора. Әҗере сез теләгәннән дә күбрәк булачак — шуннан артыгын әйтә алмыйм.

— Тагын интрига! Һаман-һаман интрига! Бик рәхмәт! Хәзер инде син мине алдый алмассың: кардинал җәнаплары кайбер нәрсәләрне төшендерде инде миңа.

— Кардинал! — дип кычкырып әйтеп куйды Бонасье ханым.— Сез кардинал белән күрештегезмени?

— Әйе, чакыртып алды ул мине,— диде галантерейчы горур бер кыяфәт белән.

— Һәм сез аның чакыруына риза булдыгызмы, саксыз бәндә?

— Дөресен генә әйткәндә, минем «барыйммы, юкмы?» дип уйланып торырга вакытым да булмады: мине анда ике сакчы алып китте. Шунысын да әйтим: кардинал хәзрәтләрен минем аңарчы күргәнем дә, белгәнем дә юк иде, әгәр мин аның янына бармый кала алган булсам, бик шат булган булыр идем.

— Сезнең белән бик дорфа сөйләштеме ул, куркытты-өркеттеме?

— Ул миңа кул биреп, мине дустым дип атады, дустым дип! Ишеттегезме, ханым? Мин бөек кардиналның дусты буламын!

— Бөек кардиналның?

— Сез аның андый дәрәҗәсеннән шикләнмисездер бит?

— Бернидән дә шикләнмим мин, тик сезгә шуны әйтәм: министрның рәхим-шәфкате — бик ышанычсыз нәрсә ул, акылыннан язган кеше генә язмышын министр белән бәйли. Аның көченнән дә югарырак торган көч-кодрәт бар әле, кешенең теләү-теләмәвенә яисә берәр хәлнең нәтиҗәсенә бәйләнмәгән көч-кодрәт бар. Әнә шундый көч-кодрәткә хезмәт итәргә кирәк.

— Бик кызганыч булса да, ханым, үзем хезмәт итә торган бөек кешенең көч-кодрәтеннән башка минем өчен бүтән көч-кодрәт юк.

— Сез кардиналга хезмәт итәсезме?

— Әйе, ханым. Һәм мин, аның хезмәтчесе буларак, сезнең дәүләт иминлегенә каршы заговорларда чуалуыгызга, тумышы белән француз булмаган, күңеле белән Испаниясен уйлап яшәгән бер хатынның интригаларына булышуыгызга юл куя алмыйм. Бәхетебезгә каршы, безнең бөек кардиналыбыз бар; аның уяу күзе һәммәсен күреп, күңел төпләренә хәтле үтеп керә.

Бонасье граф Рошфордан ишеткәннәрен сүзгә-сүз кабатлап әйтте. Бу сүзләрне ул хәтеренә ятлап калган, оста сөйләшә белүен күрсәтү өчен җай чыкканны гына көтә иде. Ә үзенең иренә өмет баглап, королеваны да өметләндергән бичара яшь ханым үз башына килә язган бәла-казадан да, чарасыз калуыннан да куркып калтырана башлады. Шулай да, иренең йомшак якларын, бигрәк тә комсызлыгын белгәнлектән, үз теләгәнен эшләтү өметеннән бөтенләй үк ваз кичеп бетмәде.

— Аһ, алай икән, димәк, сез кардиналчы, әфәндем! — диде хатын.— Аһ, сез үзегезнең хатыныгызны газаплаучы, королевагызны мәсхәрә итүче бер кешегә хезмәт итәсез икән!

— Бер кешенең генә мәнфәгате күпләрнең бәхете белән чагыштырганда берни түгел ул. Мин дәүләтне коткаручылар яклы! — диде Бонасье тантанага бирелгән сыман.

Бусы да граф Рошфор сүзләре иде, Бонасье, кирәк чакта кыстырып җибәрергә дип, моны да хәтеренә ятлап калган иде.

— Дәүләт дигән буласыз, дәүләтнең нәрсә икәнен беләсезме соң сез? — диде Бонасье ханым, җилкәсен сикертеп.— Ичмасам, әллә ниләр сөйләп мataштырмыйча, гади бер мещан булып кына калыгыз да үзегезгә күбрәк файда итүчеләр ягына басыгыз.

— Алай икән,— дип сузыбрак әйтеп куйды Бонасье, үзе янында яткан акча тулы янчыкка кулы белән суккалап алды, янчыкта көмеш тәңкәләр чыңлаганы ишетелде.— Ә менә мона нәрсә диярсез икән соң, хөрмәтле вәгазьчем?

— Каян алдыгыз бу акчаны?

— Каян икәнен төшенмисезмени?

— Кардиналданмы?

— Анардан һәм дустым граф Рошфордан.

— Граф Рошфордан? Мине урлаучы шул бит инде!

— Бик ихтимал.

— Һәм сез шул кеше кулыннан акча аласызмы?

— Сезне урлаулары бары тик сәяси сәбәпләр аркасында гына дип әйткән идегез түгелме?

— Ләкин мине урлауларының максаты мине королевама хыянәт иттерү, мине газаплап, олуг хөрмәтле ханымның абруена, хәтта тормышына куркыныч тудырырлык серләр әйттерү иде бит!

— Ханым, сезнең олуг хөрмәтле ханымыгыз — хыянәтче бер испан хатыны ул, шуңа күрә кардиналның бөтен кылган гамәле дөрес.

— Әфәндем,— дип кычкырып җибәрде яшь ханым,— мин сезнең куркак, комсыз һәм аңгыра бер җан икәнегезне белә идем, әмма бу кадәр үк түбән җанлыдыр дип уйламаган идем!

Бонасье, хатынының болай ярсынуын беренче тапкыр күреп, җәнҗал чыкмагае дип шүрләп калды һәм:

— Ханым, ханым, ни сөйлисез сез? — дип мыдырданып куйды.

— Түбән җанлы бер кеше икәнсез дим! — диде Бонасье ханым, иренә йогынтысы яңадан үтә башлаганын тоеп.— Димәк, сез, сез политика белән шөгыльләнә башлагансыз, өстәвенә әле кардинал тарафдары булып киткәнсез? Димәк, сез җаныгыз-тәнегез белән иблискә сатылгансыз, өстәвенә — акча да алгансыз?

— Иблискә түгел, кардиналга.

— Аңысы барыбер! — диде яшь ханым.— «Ришелье» дигән сүз «иблис» дигән сүз инде ул.

— Туктагыз, ханым, туктагыз! Кеше ишетер бу сүзләрегезне!

— Әйе, дөрес әйтәсез, сезнең куркак җанлылыгыгыз өчен миңа да оят булыр.

— Әйтегез әле, нәрсә кирәк соң сезгә?

— Мин сезгә әйттем бит инде: миңа сезнең шушы минутта ук юлга чыгып китүегез һәм үзегезгә тапшырылган йомышны намус белән башкарып кайтуыгыз кирәк. Шундый шартта гына мин барысын да онытырга һәм сезне гафу итәргә риза. Ул гына да түгел,— шулай дигәч, хатын иренә таба кулын сузды: — сезгә дуслыгымны да кайтарам.

Бонасье куркак җанлы, комсыз бер кеше булса да, хатынын бик ярата иде: әлеге сүздән аның күңеле нечкәреп китте. Илле яшьлек ир кешегә егерме өч яшьлек чибәр хатынына озаклап ачу тоту шактый кыен эш иде. Бонасье ханым аның әнә шулай икеләнеп калуын күрде.

— Я, ничек? Ризамы сез?

— Кадерлем, үзегез уйлап карагыз әле: нәрсә таләп итәсез сез миннән? Лондон Парижданерак, бик ерак бит, өстәвенә, ул йомышның хәвефле хәлләр белән бәйләнешле булуы да бик ихтимал.

— Ул хәвефләрдән котылып каласы булгач, барыбер түгелмени?

— Беләсезме нәрсә, Бонасье ханым? — диде галантерейчы.— Беләсезме нәрсә: андый эштән мин бөтенләй баш тартам. Интригалардан бик куркам мин. Мин бит инде Бастилияне күреп чыктым! Бр-р-р! Бастилия — коточкыч бер җир икән ул. Исемә төшсә, тәннәрем чымырдап китә. Мине газапламакчы-җәзаламакчы иделәр. Ә газаплау-җәзалауның нәрсә икәнен беләсезме сез? Аяк бармаклары арасына, сөякләр шытырдый башлаганчы, агач чөй сугалар! Юк, юк, һич булмый! Бармыйм. Ә нигә сезнең үзегезгә китеп бармаска, шайтан алгыры? Гомумән, моңарчы мин сезнең хакта ялгышканмын кебек тоела башлады: минемчә, сез ир кешедер кебек, өстәвенә ирнең дә иң чаясыдыр кебек.

— Ә сез... сез — ир кеше түгел, акылсыз, мескен һәм аңгыра бер хатын! Аһ! Сез куркасызмы? Яхшы. Алайса, шушы минутта ук мин сезне король исеменнән кулга алдыртып, котыгызны очырган шул Бастилиягә яптыртам.

Бонасье каты уйга калды. Кайсы яктан: кардинал тарафыннанмы, әллә королева ягыннанмы яманрак куркыныч килерен күз алдына кат-кат китереп чамалап карады. Кардиналның үч-ачуы хәтәррәк булырга тиеш иде.

— Мине король исеме белән кулга алдырмакчы буласызмы? — диде ул ахырында.— Ә мин кардинал хәзрәтләренә таяначакмын.

Бонасье ханым менә шунда үзенең чамадан арттырып җибәргәнлеген абайлап алды да куркуыннан сискәнеп куйды. Шүрләп калган аңгыра бер кешенең катгый тәвәккәллеген сиздергән мәгънәсез йөзенә коты чыгып күз салгалады.

— Яхшы,— диде хатын.— Ахыр чиктә, бәлки, сез хаклысыздыр да. Ирләр политиканы яхшырак аңлый, кардинал белән әңгәмә дә кылган булгач, сез инде, Бонасье әфәнде, бигрәк тә. Шулай булса да мин сезгә бик рәнҗедем,— дип дәвам итте ханым,— үземне бик ярата дип ышанып йөргән ирем минем теләгемне үтәүдән баш тартты.

— Сезнең теләкләр хәтәр якка да алып китүе ихтимал шул,— диде Бонасье, юл куючан бер тавыш белән.— Андый теләкләрдән куркам шул мин.

— Болай булгач, ул ниятемнән ваз кичәргә туры килә инде,— диде яшь ханым, көрсенеп.— Ярар, шулай булсын. Ул хакта бүтән сөйләшмик.

Бонасье, беравык дәшми торганнан соң, Рошфор аңа хатынының эч серләрен төпченергә кушканлыгын исенә төшереп, сүзгә кереште:

— Минем Лондонга барып нишләргә тиешлегемне, ичмасам, рәтләбрәк аңлаткан булсагыз икән.

— Сезгә анысын белүнең кирәге юк,— диде яшь ханым, иренә карата уянган шиге хәзер аны ихласлыгыннан тыеп тора иде инде,— кайвакыт хатын-кызга бик кирәк булып куя торган кеч-

кенә бер нәрсә, бизәк әйберсе турында иде сүз, шул эштә яхшы гына акча төшереп була иде.

Яшь ханым эчендәге уйларын яшерергә тырышкан саен, Бонасье хатынының әйтергә теләмәгән нәрсәсе шактый зур бер сер икәнлегенә ышана барды. Шуңа күрә ул хәзер үк граф Рошфор янына чыгып чабарга һәм королеваның Лондонга җибәрү өчен атчабар эзләвен белгертергә карар итте.

— Гафу итегез, кадерлем, мин беразга сезнең үзегезне генә калдырып торырга тиешмен,— диде Бонасье.— Мин, сезнең бүген кайтасыгызны белмичә, бер дус белән күрешергә дип вәгъдәләшкән идем. Озак тормам, чак кына көтсәгез, дустым белән сүземне бетергәч тә сезнең янга кайтам. Әнә тышта караңгы да төшеп килә инде — мин сезне Луврга озатып куярмын.

— Бик рәхмәт, әфәндем,— диде Бонасье ханым.— Миңа андый ярдәм күрсәтерлек батыр кеше түгел сез. Луврга мин үзем дә кайта алам.

— Ихтыярыгыз, Бонасье ханым,— диде галантерейчы булган кеше.— Мин сезне кабат кайчан күрә алырмын икән инде?

— Бәлки, киләсе атнада бераз эшемнән бушап өйгә кайта алырмын: өйдәге әйберләрне тәртипкә китерәсе бар, аларга да бераз зарар тими калмагандыр.

— Яхшы алайса, мин сезне көтәрмен. Сез миңа ачуланмыйсыздыр бит?

— Минме? Тамчы да юк.

— Димәк, озакламый күрешербез? Сау булыгыз.

— Әйе, сау булыгыз.

Бонасье әфәнде хатынының кулын үпте дә ашыга-ашыга чыгып китте.

Ире артыннан тышкы ишек ябылып, Бонасье ханым өйдә ялгызы гына калгач:

— Әйе, бу тинтәккә кардиналчы булу гына җитмәгән иде шул. Мин бит королевага ярдәм итәм дип ышандырдым, бичара королевама сүз бирдем... Ай аллам, ай аллам! Хәзер ул мине король сараенда мыжлап торган, шымчылык итү өчен үзе янына урнаштырылган түбән җаннарның берсе дип санаячак бит... Аһ, Бонасье әфәнде!.. Мин сезне моңарчы да әллә ни яратмый идем, ә хәзер тагы да яман: мин сезне дошман күрәм һәм сезнең белән исәп-хисапны өзәргә сүз бирәм,— дип сөйләнде.

Шул чагында югарыдан түшәм шакыганнары ишетелде, хатын башын күтәреп карады. Түшәм аша кемнендер:

— Кадерле Бонасье ханым, баскычтагы кечкенә ишекне ачыгыз әле, мин сезнең яныгызга төшәм! — дигәне ишетелде.

## XVIII

## МӘГЪШУГ ЕГЕТ БЕЛӘН ИР

Д'Артаньян яшь ханым ачкан ишектән керә-керешли үк әйтте:

— Әйе, ханым, әйтсәм әйтим: ирегез бик куркак бер адәм аламасы икән,— диде.

Бонасье ханым, хафаланган бер төс белән д'Артаньянга карап, шундук сорады:

— Димәк, безнең сөйләшкәнне ишетеп тордыгыз сез?

— Башыннан азагына кадәр.

— Ничек ишетә алдыгыз сез, ай аллам?!

— Кардинал шымчылары белән сезнең арадагы теге тавышлырак әңгәмәне ничек ишеткән булсам, бу юлы да нәкъ шулай ишеттем.

— Безнең үзара сөйләшүебездән ниләр аңлап калдыгыз соң?

— Бик күп нәрсә аңлап калдым. Беренчедән, бәхеткә каршы, ирегез ахмак һәм тинтәк бер кеше икән; икенчедән, сез бик кыен бер хәлдә калгансыз, бу хәлгә мин әйтеп бетергесез шатмын, ник дигәндә, бу очракта мин сезгә бер-бер ярдәм күрсәтә алачакмын. Менә ходай шаһит: сезнең хакка мин дөрләп янган ут эченә ташланырга да әзермен; һәм, ниһаять, королевага аның йомышы белән Лондонга чыгып китәрдәй кыю, зирәк һәм турылыклы бер кеше кирәк икән, һәрхәлдә, ул сыйфатларның кайберләре миндә бар, шуңа күрә мин сезнең әмерегезне көтәм.

Бонасье ханым тиз генә җавап кайтармады, шулай да сөенечтән аның йөрәге дөп-дөп тибә, күзләрендә өмет чаткылары ялтырый башлады.

— Ә мин нәрсәгә ышанып сезгә ул эшне тапшыра алам соң? — дип сорады ханым.

— Минем сезне сөюем ышаныч булсын. Я, әйтегез инде, әмерегезне бирегез! Нәрсә эшләргә тиеш мин?

— Йа раббым,— дип пышылдады яшь ханым,— андый серне мин сезгә ышанып тапшыра алам микән соң?! Сез бит әле сабый бала диярлек!

— Сезгә берәрсенең минем өчен ышаныч бирүе кирәк, күрәсең.

— Ихластыр, шуннан соң минем җаным тыныч булыр иде.

— Атосны беләсезме сез?

— Юк.

— Портосны?

— Юк.

— Арамисны?

— Юк. Кемнәр алар — ул әфәнделәр?

— Король мушкетерлары. Аларның капитаны де Тревиль әфәндене беләсезме?

— Әйе! Мин аны беләм — тик күреп түгел, ишетеп кенә беләм. Королеваның аның хакында яхшы күңелле, намуслы дворян дип әйткәне бар.

— Аның сезне кардинал файдасына сату ихтималын күз алдыгызга китермисездер бит?

— Юк, әлбәттә.

— Шулай булгач, сез аңа серегезне әйтегез дә, шул бик мөһим, бик кадерле һәм бик хәтәр серегезне миңа ышанып тапшырырга мөмкинме? — дип сорагыз.

— Кызганычка каршы, ул минем үз серем түгел шул, минем аны башкаларга чишәргә хакым юк!

— Бонасье әфәндегә ул серне чишәргә җыенган идегез ич әле! — диде д'Артаньян, хәтере калып.

— Агач куышына, күгәрчен канатына яки эт муенчагына хат ышанып тапшырган кебек.

— Минем сезне никадәр яратканымны күреп торасыз бит!

— Әйе, шулай дисез.

— Мин намуслы кешемен!

— Мин дә шулай дип уйлыйм.

— Мин батырмын.

— О, анысын бик яхшы беләм.

— Шулай булгач, сынап карагыз соң мине.

Бонасье ханым, соңгы шик-шөбһәләрен җиңәргә тырышып, егеткә күтәрелеп карады. Егетнең күзләре очкынланып янганлыгын, ышанычлы, нык тавыш белән сөйләшүен күреп, ханымның күңелендә аңа ышаныч тойгысы уянды. Шулай булмаска, башка чарасы юк иде бит аның. Тәвәккәлләргә туры килә иде. Артык ышану хәтәр булган кебек, артык сак булу да королева өчен зарарлы иде. Аннары,— без монысын да әйтми китә алмыйбыз,— бу егеткә карата күңелендә туган тойгы да ханымны серен чишәргә мәҗбүр итте.

— Ишетәсезме: мин сезнең теләгегезгә юл куям, сезгә ышанырга булдым,— диде ханым.— Әмма үзебезне ишетеп торган ходай каршында ант итеп әйтәм: әгәр дә мәгәр сез миңа хыянәт итсәгез, дошманнарым мине кичерсәләр дә, сезне үземнең үлемем өчен гаепле санап, дөньядан ваз кичәчәкмен.

— Мин дә ходай каршында ант итеп әйтәм: әгәр дә мәгәр сезнең йомышны үтәгән чагымда дошман кулына эләгеп, берәр кешегә тап төшерерлек бер сүз әйтсәм яки эш кылсам, дөньяда яшәүдән үлүем мең өлеш артыграк булыр,— диде д'Артаньян.

Шуннан соң инде яшь ханым егеткә серен сөйләп бирде — Самаритянка каршындагы күпердә булган хәл безгә ул сернең беркадәр өлешен ачкан иде инде.

Сер чишү аларның мәхәббәт аңлашулары да булды.

Д'Артаньян шатлык һәм горурлык тойгысыннан нишләргә белмәде. Үзенә ышанып тапшырылган сер һәм сөйгән ханымы бетмәс-төкәнмәс көч-куәт бирде аңа.

— Китәм. Шушы минутта ук китәм! — диде егет.

— Ничек китәсез? — диде Бонасье ханым.— Ә полк, командирыгыз?

— Җаным белән ант итеп әйтәмен: сез, кадерле Констанция, дөньядагы бөтен нәрсәне оныттырдыгыз! Сүзегез хак, миңа ял алырга кирәк.

— Тагын комачаулык! — дип хафаланып пышылдап куйды Бонасье ханым.

Д'Артаньян беравык уйланып торды да әйтте:

— О, ул комачаулыкны бик тиз бетерәм мин, бер дә борчылмагыз.

— Ничек бетерәсез?

— Бүген кич де Тревиль әфәнде янына барам да кияве Дезэссар әфәндедән миңа ял бирдертәм.

— Ләкин аның белән генә эш бетми бит әле...

— Сезне тагын нәрсә борчый соң? — диде д'Артаньян, Бонасье ханымның сүзне дәвам иттерергә кыймавын күреп.

— Сезнең, бәлки, акчагыз юктыр?

— «Бәлки» дигәнегез артык,— диде д'Артаньян елмаеп.

— Алайса, менә бу янчыкны алыгыз,— дип, Бонасье ханым шкафтан әле ярты сәгать кенә элек ире сокланып сыйпаштырып торган янчыкны алып бирде.

— Кардинал янчыгы! — дип, д'Артаньян шаркылдап көлеп җибәрде; белгәнебезчә, бая ул идән тишегеннән ир белән хатын сөйләшкәнне баштанаяк тыңлап торган иде бит.

— Әйе шул, кардинал янчыгы,— диде Бонасье ханым да.— Күрәсез: шактый саллы күренә.

— Ах, шайтан! Кардинал хәзрәтләренең акчасы белән королеваны коткару үзе генә дә ни тора бит,— дип куйды д'Артаньян.

— Сөекле егетем, ышаныгыз: олуг ханым бурычлы булып калмас сезнең алда.

— О, мин инде бөтен әҗерен алдым! — диде д'Артаньян.— Мин сезне сөям, сез миңа сөям дип әйтергә рөхсәт итәсез. Мондый бәхеткә ирешәсемне уема да китерә алмый идем бит!

Кинәт Бонасье ханым калтыранып:

— Әкренрәк! — дип пышылдады.

— Нәрсә бар?

— Урамда кешеләр сөйләшә...

— Тавыш бармы?..

— Ирем кайта. Әйе, мин аның тавышын таныйм!

Д'Артаньян ишеккә йөгереп барып бикләп ишереп куйды.

— Мин китмичә монда кермәячәк ул. Мин киткәч ишекне ачарсыз.

— Мин дә китәргә тиеш ләбаса. Мин монда калсам, акчаның юкка чыгуын ни дип аңлатып бирермен мин аңа?

— Сүзегез хак, моннан таярга кирәк.

— Таярга? Ничек итеп? Чыксак, безне күрә ич ул.

— Алайса, миңа менәргә кирәк.

— Аһ! — дип куйды Бонасье ханым.— Сез моны шундый итеп әйтәсез — йөрәгемә курку саласыз.

Шулай дигәндә Бонасье ханымның күзендә яшь бөртекләре елтырап китте. Д'Артаньян моны күреп аптырый калды, күңеле йомшап китеп, ханымның аягына егылды.

— Минем бүлмәдә сезгә, храмдагы кебек, бернинди куркыныч булмас, дворян сүзе бу,— диде.

— Әйдәгез алайса. Сезгә ышанып тапшырам үземне, дустым,— диде ханым.

Д'Артаньян ишекнең биген сакланып кына кире ачты, һәм алар, күләгә шикелле генә шуып, эчке ишек аша баскыч идәненә чыктылар да баскычтан тып-тын гына менеп, д'Артаньян бүлмәсенә кереп киттеләр.

Үз бүлмәсенә кергәч, егет, ышанычлырак булсын өчен, ишекне терәтеп үк куйды. Аннары алар, тәрәзәдән карап, Бонасье әфәнденең баштанаяк плащ бөркәнгән ят бер кеше белән сөйләшеп торганын күрделәр.

Д'Артаньян плащлы кешене күрү белән тетрәнеп китте дә, кылычын яртылаш чыгарып, ишеккә ташланды.

Плащлы кеше теге Мёнгта очраган ят бәндә иде.

— Нишләмәкче буласыз? Икебезне дә харап итәсез бит! — дип кычкырды Бонасье ханым.

— Мин ул кешене үтерергә ант иттем! — диде д'Артаньян.

— Сез хәзер үзегезгә үзегез хуҗа түгел, гомерегезне үтисе бурычыгызга багышладыгыз. Үзегезне, сәяхәтегездә очрардай хәвеф-хәтәрләрдән кала, башка куркыныч астына куюны королева исеменнән катгый тыям мин сезгә.

— Ә үз исемегездән сез миңа бернинди дә әмер бирмисезме?

— Үз исемемнән...— дип куйды Бонасье ханым бик нык дулкынланып,— үз исемемнән дә нәкъ шуны ялварып сорыйм. Тыңлап карыйк әле — алар минем хакта сөйләшә шикелле.

Д'Артаньян тәрәзә янына килеп, тышка колак салды.

Бонасье әфәнде йортының ишеген ачкан иде инде, квартирда кеше юклыгын күргәч, ул плащлы кеше янына кире килде.

— Хатыным чыгып киткән,— диде Бонасье.— Луврга кайтып киткәндер.

— Хатыныгыз сезнең нинди максат белән киткәнегезне сизенмәгәндер дип ышанасызмы? — дип сорады плащлы кеше.

— Әйе,— диде Бонасье ваемсыз гына.— Ул кадәресен сизенерлек түгел ул, артык җилбәзәк хатын.

— Ә гвардияче егет өйдәме соң?

— Юктыр дип беләм. Әнә, күрәсез бит тәрәзә капкачлары ябык, ярыкларыннан бернинди якты төшми.

— Шулай да, тикшереп карау зыян итмәс.

— Ничек итеп?

— Ишеген шакып карарга кирәк.

— Мин аны хезмәтчесеннән сорыйм.

— Барыгыз.

Бонасье подъездга керен китте, әле яңа гына теге качаклар узган ишек аша үтте дә д'Артаньянның ишек төбенә килеп шакып карады.

Җавап бирүче булмады: Портос бүген кичкә, үзен тагы да җиллерәк күрсәтү өчен, Планшены сорап торган иде, д'Артаньянга килгәндә исә, ул тавыш-тынын чыгармаска тырышты.

Бонасье әфәнде ишекне дөбердәтергә үк керешкәч, яшь ханым белән егетнең йөрәкләре дөп-дөп сикерә башлады.

— Беркем юк анда,— диде Бонасье.

— Шулай да, сезгә керик әле. Урамда торуга караганда анда тынычрак булыр.

— Аһ! Хәзер инде берни ишетмәячәкбез,— дип куйды Бонасье ханым.

— Киресенчә, хәзер без тагы да яхшырак ишетәчәкбез,— диде д'Артаньян, хатынны тынычландырырга тырышып.

Ул идәндәге берничә паркет шакмагын куптарып, читкә алып куйды,— шулай итеп, аның идәне Дионисий колагы шикелле бер нәрсәгә әйләнде,— идәнгә келәм җәеп келәмгә тезләнде дә ымлап кына Бонасье ханымга да шулай итәргә, идән ярыгы өстенә иелергә кирәклеген аңлатты.

— Өйдә беркем юк дип тәгаен ышанып әйтәсезме? — дип сорады ят кеше.

— Моның өчен мин җавап бирәм,— диде Бонасье.

— Хатыныгыз инде...

— Сарайга кайтып киткән дип уйлыйм.

— Аңарчы беркем белән дә сөйләшмәгән дисезме?

— Һичшиксез шулай.

— Моны тәгаен белү бик кирәк, беләсезме?

— Димәк, мин сезгә биргән мәгълүматларны кыйммәтле дип санарга мөмкин?

— Сездән яшермим, кадерле Бонасье, бик кыйммәтле мәгълүматлар.

— Димәк, кардинал миннән бик канәгать булачак?

— Һичшиксез.

— Галиҗәнап кардинал!

— Хатыныгыз сезнең белән сөйләшкән чакта беркем исемен дә телгә алмавын яхшы хәтерлисезме?

— Алмады шикелле.

— Де Шеврез ханым исемен, я герцог Бекингэм яки де Верне ханым исемен телгә алмадымы?

— Юк, бер бик олуг дәрәҗәле кешенең йомышы белән мине Лондонга җибәрергә ниятләвен генә әйтте.

— Хаин! — дип пышылдады Бонасье ханым.

— Әкренрәк,— диде д'Артаньян, ханымның кулын тотты, тегесе, уйларына бирелеп, кулын тартып алмады.

— Шулай да риза булганга салышмыйча акылсызлык эш-

ләгәнсез,— диде плащлы кеше.— Менә хәзер ул хат безнең кулда булыр иде инде, дәүләтебез куркынычлыктан котылган булыр иде, ә сез...

— Ә мин?..

— Ә сез... дворян дәрәҗәсе алган булыр идегез.

— Сезгә әйттеме ул...

— Әйе, мин аның шушы көтелмәгән сөенечне әйтеп сезне шатландырырга теләгәнен беләм.

— Бер дә борчылмагыз. Хатыным мине бик ярата. Әле хәзер дә соң түгел,— диде Бонасье.

— Ахмак! — дип пышылдады Бонасье ханым.

— Әкренрәк! — дип чак ишетелерлек итеп кенә пышылдады д'Артаньян, хатынның кулын катырак кысты.

— Ничек ул «соң түгел»? — дип сорады плащлы кеше.

— Луврга барып, Бонасье ханымны чакырып чыгарам да, мин барырга булдым, башкарып кайтам, дип әйтәм, хатны кулга төшерү белән кардиналга йөгерәм.

— Яхшы алайса. Ашыгыгыз, сезнең нәрсәгә ирешкәнегезне белер өчен мин озакламый кире килермен.

Шулай дигәч, ят кеше чыгып китте.

— Кабахәт! — диде Бонасье ханым үз иренә карата.

— Әкренрәк! — диде д'Артаньян, ханымның кулын тагы да катырак кысып.

Шул минутта шырылдап кычкырган әллә нинди бер аваз д'Артаньян белән Бонасье ханымны сискәндереп уйларыннан айнытып җибәрде. Бонасье ханымның ире, бер янчык акчасы юкка чыкканлыгын күреп, ярдәмгә кешеләр чакыра башлаган иде.

— Ай аллам, ай аллам! Бөтен квартал халкын аякка бастыра бит хәзер! — диде Бонасье ханым.

Бонасье шактый озак кычкырды. Каберчеләр урамында мондый авазлар еш кына ишетелгәнлектән, моңа берәү дә әһәмият итмәде, өстәвенә, галантерейчы йортының бу араларда җәнҗаллы дигән даны да чыккан иде, шуңа күрә Бонасье, бер кеше дә килмәвен күреп, кычкыра-кычкыра йорттан йөгереп чыкты. Аның Дюбак урамы ягына таба аһ ора-ора китеп баруы байтак вакыт ишетелеп торды.

— Хәзер инде, ул чыгып киткәч, сезнең чират — барыгыз,— диде Бонасье ханым.— Батыр булыгыз, аннан да бигрәк сак булыгыз. Тик шуны онытмагыз: сез хәзер королевага тапшырылгансыз.

— Аңа да, сезгә дә! — диде д'Артаньян.— Бер дә борчылмагыз, гүзәл Констанция. Мин аның рәхмәтенә лаеклы булып әйләнеп кайтырмын, тик менә сезнең мәхәббәтегезгә лаеклы була алырмынмы икән?

Яшь ханымның кызарып киткән ике бите егетнең бу сүзенә җавабы булды. Берничә минуттан соң инде д'Артаньян үз нәүбәтендә йорттан чыгып китте — ул өстенә плащ бөркәнгән, озын

кылыч кынысы аның бөтен кыяфәтенә көч-гайрәт биреп, плащ чабуын күтәреп тора иде.

Бонасье ханым ягымлы-назлы карашын тегәп егет артыннан карап калды — йөрәгендә сөю хисләре уяткан ир-егетне хатын-кыз әнә шундый күз карашы белән озатып кала.

Д'Артаньян инде урам чатына китеп югалгач, ханым идәнгә тезләнде дә кулларын уа-уа:

— И раббым! Ярдәменнән ташлама королеваны, ярдәменнән ташлама мине! — дип пышылдады.

## *XIX*

## *КАМПАНИЯ ПЛАНЫ*

Д'Артаньян башта де Тревиль әфәнде янына китте. Ул кардиналга тәгаен аның ышанычлы кешесе булган теге ят адәм аша берничә минуттан ук барысы да мәгълүм булачагын белә, шуңа күрә бер генә минутны да әрәм итәргә ярамый дип уйлый иде.

Егетнең шатлыгы эченә сыймый. Һич уйламаганда-көтмәгәндә ана дан-шөһрәт казанырга да, акчалы булырга да форсат килеп чыкты бит, өстәвенә әле бу форсат ул өзелеп сөйгән хатын белән аралары якыная төшүгә дә сәбәпче булды. Тәкъдире аңа хыялына да килмәслек зур бер бәхет китереп тоттырды.

Де Тревиль әфәнде үзенең кунак бүлмәсендә гадәттәге зур дәрәҗәле дуслары белән мәҗлес корып утыра иде. Д'Артаньян, бу йорттагы бөтен кешегә таныш булганлыктан, туп-туры кабинетка узды да хезмәтче аша капитанга бик мөһим сүзе барлыгын әйттерде.

Шуннан соң биш минут та узмагандыр — кабинетка де Тревиль әфәнде килеп керде. Егетнең шатлыктан балкыган йөзенә бер күз салу да җитте — мөхтәрәм капитан ниндидер яңа бер хәл булганлыгын төшенде.

Бирегә килгән чагында егет, де Тревиль әфәндегә ышанып серне чишәргәме, әллә аннан бер яшерен эш башкару өчен ирек бирүен генә сораргамы? — дип юл буе баш ватып килде. Әмма де Тревиль әфәнде егеткә һәрвакыт бик яхшы, гадел мөнәсәбәт күрсәтә, король белән королевага зур тугрылык саклый, кардиналны бик нык күралмый иде — шул сәбәпле егет, серен яшереп кала алмыйча, барысын сөйләп бирергә карар итте.

— Минем кабул итүемне сорагансыз икән, дускаем,— диде де Тревиль.

— Әйе, әфәндем, бик мөһим бер эш хакында сөйләячәгемне белеп борчылсагыз, мине гафу итәрсез инде,— диде д'Артаньян.

— Әйдә алайса, сөйләгез. Тыңлыйм.

— Аз да түгел, күп тә түгел,— дип кереште д'Артаньян тавышын әкренәйтә төшеп,— королеваның абруе турында, хәтта ки аның тормышы турында бара сүз.

— Ни сөйлисез! — дип куйды де Тревиль, берәрсе ишетмиме икән дигәндәй як-ягына каранып алды да кызыксынулы күз карашын яңадан егеткә төбәде.

— Шуны әйтәм, әфәндем, бер форсат миңа бер сер ачты...— диде д'Артаньян.

— Сез ул серне, егетем, җаныгызны бирергә туры килсә дә эчегездә сакларга тиешсез.

— Шулай да, әфәндем, мин ул серне сезгә чишәргә тиешмен, чөнки олуг ханым йөкләгән ул бурычны башкарып чыгуда миңа бары тик сез генә ярдәм итә аласыз

— Ул сер сезнең үзегезнекеме?

— Юк, әфәндем, ул сер королеваныкы.

— Сезгә ул серне миңа чишәргә олуг ханым рөхсәт иттеме соң?

— Юк, әфәндем, киресенчә әле: миңа аны беркемгә дә белгертмәскә әйтелде.

— Шулай булгач, нигә сез аны миңа чишәргә җыенасыз?

— Чөнки, әйткәнемчә, сезнең ярдәмегездән башка мин берни эшли алмаячакмын, әгәр сез ни өчен икәнен белмәсәгез, минем үтенечемне кире кагарсыз дип куркам.

— Үзегезгә ышанып тапшырылган серне эчегездә генә саклагыз, егетем, һәм теләгегезне әйтегез.

— Теләгем шул: сез миңа Дезэссар әфәндедән ике атнага ял бирдертсәгез иде.

— Кайчан?

— Бүгенге төннән башлап?

— Сез Париждан чыгып китәсезме?

— Тапшырылган йомышны үтәргә китәм мин.

— Кая китәсегезне миңа әйтә аласызмы?

— Лондонга китәм.

— Сезне анда бардыртмаска теләүчеләр бармы?

— Минемчә, кардинал миңа комачаулык итәр өчен дөньядагы бер нәрсәсен дә кызганмас иде.

— Юлга бер үзегез генә чыгып китәсезме?

— Үзем генә китәм.

— Ул чагында сез Бондидан ары китә алмассыз, менә де Тревиль әйткән иде, диярсез.

— Нигә?

— Артыгыздан сезне үтерергә кеше җибәрәчәкләр.

— Мин үземнең бурычымны үтәгәндә үләм бит.

— Әмма бурычыгыз үтәлми калачак.

— Анысы хак...— диде егет.

— Шуны белегез: берәү барып җитсен өчен, андый юлга дүртәү чыгарга кирәк,— диде де Тревиль.

— Әйе, сүзегез хак, әфәндем,— диде д'Артаньян.— Сез инде Атос, Портос һәм Арамисны беләсез, минем аларны ярдәмгә ала алуымны да беләсез.

— Мин үзем дә белергә теләмәгән серегезне аларга да чишмичә генәме?

— Без бер-беребезгә сүзсез дә ышанырга һәм бер-берегә һәрвакыт турылыклы булырга дип гомерлеккә ант иттек. Аннары, сез аларга: «д'Артаньянга тулысынча ышанам»,— дип тә әйтә аласыз, шуннан соң алар миңа да сезгә ышанган кебек ышаначаклар.

— Мин аларның һәркайсына икешәр атна ял бирә алам: Атосның әле һаман ярасы төзәлеп бетмәгән,— ул Форжга шифалы су белән дәваланырга китәр, Портос белән Арамис аны озата барырлар,— дусларын шундый авыр хәлдә ялгыз калдыра алмыйлар бит инде. Ялга чыгу турындагы таныклык юлга минем ризалык белән чыкканлыкларын раслар.

— Рәхмәт сезгә, әфәндем. Сез бик зур яхшылык кыласыз.

— Хәзер үк алар янына китегез. Бүген төнлә үк юлга чыгарга тиешсез... Әйе, ә хәзер Дезэссар әфәнде исеменә үтенеч язып калдырыгыз. Ихтимал, хәзер инде артыгыздан шымчы күзәтеп йөридер, шуңа күрә сезнең минем янга килүегезне кардинал белми калмаса да, сәбәбе нигезле булачак.

Д'Артаньян әлеге үтенечне язды, һәм де Тревиль Гасконь егетенең кулыннан үтенечне алган чагында әйтте: ике сәгатьтән дә артык соңгармыйча ял алу хакындагы дүрт таныклык юлга чыгасы дүрт кешенең һәркайсының квартирында булыр, диде.

— Минем таныклыкны Атоска җибәрегезче. Үз өемә кайтып кергәч, берәр күңелсез хәлгә юлыкмагаем дип куркам,— дип үтенде д'Артаньян.

— Бер дә борчылмагыз. Сау-сәламәт булыгыз, хәерле юл сезгә... Ә, әйе, сабыр итегез әле! — дип кычкырды де Тревиль, д'Артаньянны туктатып.

Д'Артаньян кире килде.

— Акчагыз бармы?

Д'Артаньян кесәсендәге акча янчыгына бармагы белән чертеп күрсәтте.

— Җитәрлекме соң? — дип сорады де Тревиль.

— Өч йөз пистоль.

— Бик шәп. Ул акча белән җәһәннәмгә дә барып житеп була. Ярый алайса, хәерле юл!

Д'Артаньян башын иеп де Тревиль белән саубуллашты, капитан аңа кул сузды. Гасконь егете дә ихтирам белән рәхмәтен белдереп аның кулын кысты. Парижга килгән көненнән башлап, бик кешелекле, намуслы һәм киң күңелле бу кеше белән ул мактанып бетә алмый иде.

Д'Артаньян иң элек Арамиска сугылды. Аның инде теге Бонасье ханымны күзәткән кичтән бирле дусты янына кергәне юк иде. Ул гына да түгел, соңгы вакытларда д'Артаньян муш-

кетер егет белән бик сирәк очраша һәм аны күргән саен дустының чыраенда ниндидер зур кайгы галәмәтләре бар кебек сизә иде.

Арамис бу кичне дә йокларга ятмаган, үзе уйчан, чырае караңгы иде. Д'Артаньян аның ни сәбәпле болай ямансылавын сораштырып та карады. Арамис изге Августинның унсигезенче сүрәсенә шәрех язасы барлыгын сәбәп иткән булды, киләсе атнага шул шәрехне латинча язып бетерергә тиеш, шуңа бик борчыла икән.

Ике дусның әңгәмәсе шул рәвешчә берничә минут дәвам иткәч, кинәт де Тревиль әфәнденең бер хезмәтчесе килеп кереп, Арамиска ябык пакет тапшырды.

— Нәрсә бу? — дип сорады мушкетер.

— Ялга чыгарга рөхсәт, үзегез сорагансыз бит, әфәндем,— дип җавап бирде хезмәтче.

— Минем ял сораганым юк ич! — диде Арамис.

— Күп сөйләшми генә алып калыгыз,— дип пышылдады аңа д'Артаньян.— Менә сезгә, дустым, хезмәтегез өчен ярты пистоль,— диде аннары хезмәтчегә эндәшеп.— Де Тревиль әфәндегә кайтып әйтегез: Арамис әфәнде чын күңеленнән рәхмәтен белдерде, диегез.

Хезмәтче җиргә чаклы бөгелеп баш иде дә чыгып китте.

— Бу ни хикмәт? — дип сорады Арамис.

— Ике атналык сәяхәттә кирәк булырлык бөтен әйберләрегезне җыеп төйнәгез дә миңа ияреге.

— Тик мин хәзер үк Парижданчыгып китә алмыйм бит, нине белмичә...— дип, Арамис сүзеннән киселеп калды.

— ...Ул ханымга ни булганын белмичәме? — дип, аның сүзен ялгап алып китте д'Артаньян.

— Нинди ханым? — дип сорады Арамис.

— Шушында булып киткән ханым, чиккән яулыклы ханым.

— Кем әйтте сиңа монда хатын-кыз булып киткән дип? — диде Арамис, көл төсле агарынып.

— Мин аны үзем күрдем.

— Кем икәнен дә беләсезме?

— Һәрхәлдә чамалыйм.

— Карагыз әле,— диде Арамис.— Сез алай бик күп белгәч, шунысын да әйтеп бирерсез, бәлки: ул хатын нишләде икән?

— Турга кайтып киткәндер дип беләм.

— Турга?.. Әйе шул, алай булуы да ихтимал. Сез аны беләсез икән. Ничек ул алай, миңа бер сүз дә әйтмичә, Турга кайтып китте икән соң?

— Үзен кулга алмагайлары дип курыккан ул.

— Алайса ни өчен миңа язып калдырмаган?

— Сезгә бәла китерәсе килмәгән.

— Д'Артаньян! Сез минем җанымны тергездегез! — дип кычкырып җибәрде Арамис.— Мине яратмыйлар, алдап кына йөртәләр дип уйлаган идем мин. Аның белән янадан күрешүемә

шундый шатландым. Мин аның минем хакка үз ирекен шулай куркыныч астына куюын уема да китермәдем, әмма, икенче яктан, нинди сәбәп аны Парижга кайтырга мәҗбүр итте икән соң?

— Без бүген нинди сәбәп белән Англиягә китсәк — шул сәбәп...

— Ә нинди сәбәп соң ул? — дип сорады Арамис.

— Вакыты җиткәч белерсез әле, Арамис. Хәзергә мин, теге *динченең сеңлесен* истә тотып, артык бер сүз дә әйтә алмыйм.

Арамис, кайчандыр дусларына сөйләгән әкиятне хәтерләп, елмаеп куйды.

— Ярый алайса, ул инде Париждан киткән икән, сез моны бик ышанып әйтәсез икән, ул чагында мине монда тотып торырлык сәбәп юк, мин сезнең белән бергә юлга чыгып китәргә әзермен. Сез бит Англиягә барабыз дип әйттегез?..

— ...Иң элек Атос янына барабыз, әгәр минем белән бергә барырга уйласагыз, ашыга төшәргә киңәш итәм, чөнки без инде болай да вакытны күп әрәм иттек. Шунысын да искәртим: Базенга әйтеп куегыз.

— Базен да безнең белән китәмени?

— Ихтимал. Һәрхәлдә, аның да Атос янына баруы файдалы булыр.

Арамис Базенны чакырып алды да үзләре артыннан Атос квартирына барырга кушты.

— Алайса, киттек,— диде Арамис, плащы белән кылычын алды, бил каешы астына өч пистолет кыстырды. Берәр тәңкә тапмаммы дип берничә тартманы ачып карады. Акча калмаганлыгын күргәч, д'Артаньян артыннан ишеккә таба атлады, көенеп: «Бу гвардияче егет миндә кунак булып киткән хатынның кем икәнлеген каян белде икән? Ул хатынның кая китеп барганлыгын ничек ул миннән дә яхшырак белә икән?» дип уйланды.

Ишек төбенә җиткәч, Арамис д'Артаньянның җилкәсенә кулын куйды да:

— Сез әлеге хатын турында беркемгә бер сүз дә әйтмәдегезме? — дип сорады.

— Беркемгә дә әйтмәдем.

— Атос белән Портоска дамы?

— Ләм-мим.

— Алайса аллага шөкер икән!

Бу борчуыннан тынычлангач, Арамис д'Артаньян белән бергә Атос янына китте. Озакламый алар Атос яшәгән йортка да җиттеләр.

Болар килеп кергәндә, Атос бер кулына ял бирү турындагы рөхсәт кәгазен, икенчесенә де Тревиль әфәнденең хатын тотып басып тора иде.

— Бу ял дигәннең һәм әле генә алган шушы хатның нәрсә икәнлекләрен аңлатып бирә алмассызмы? — диде ул гаҗәпкә калган бер төс белән.

«Кадерле Атос, сезнең сәламәтлегегез өчен бик кирәк булгач, мин сезгә ике атнага ял бирергә ризамын. Форжга шифалы су белән дәваланырга яки үзегез теләгән башка бер җиргә бара аласыз. Тизрәк сәламәтләнеп житегез.

Сезгә илтифат белән
*Тревиль*».

— Бу хат белән ял — сез минем белән китәргә тиешсез дигән сүз ул, Атос.

— Форжга шифалы сугамы?

— Я шунда, я икенче бер җиргә.

— Корольгә хезмәт итү максаты беләнме?

— Король белән королевага. Без ул галиҗәнапларның хезмәтчеләре түгелмени?

Нәкъ шул минутта Портос та килеп керде.

— Шайтан алгыры! — диде ул керә-керешли үк.— Кайчаннан бирле әле мушкетерларга үзләре сорамыйча ук ял бирә башлаганнар?

— Алар өчен тырышучы дуслары булганнан бирле.

— Әһә...— дип куйды Портос.— Мөгаен, монда бер-бер яңалык бардыр.

— Әйе, сәфәр чыгабыз,— диде Арамис.

— Кай тарафларга? — дип сорады Портос.

— Ихластыр, җүнләп белмим дә. Д'Артаньяннан сора,— диде Атос.

— Әфәнделәр, без Лондонга китәбез,— диде д'Артаньян.

— Лондонга! — диде Портос исе китеп.— Нишлибез без ул Лондонда?

— Менә анысын инде әйтергә хакым юк, әфәнделәр. Сез миңа ышанырга тиеш буласыз.

— Лондонга барыр өчен акча кирәк бит. Ә минем акчам юк,— диде Портос.

— Минем дә юк.

— Минем дә.

— Акча миндә бар,— дип, д'Артаньян кесәсендәге байлыгын чыгарып өстәл өстенә ташлады.— Бу янчыкта өч йөз пистоль акча бар. Һәркайсыбыз җитмеш бишәрне алса, Лондонга барырга да, кайтырга да җитә. Хәер, борчылмагыз: бөтенебез дә Лондонга барып җитмәс.

— Нигә?

— Ник дигәндә, кайберебезнең юлда аерылып калуы ихтимал.

— Ничек бу — без походка чыгып китәбезмени?

— Кисәтеп куйыйм: бик куркыныч юлга чыгабыз.

— Ах, шайтан алгыры!— диде Портос.— Алай безнең үлеп калуыбыз куркынычы да булгач, һич югы, беләсе иде: нәрсә хакына үләбез соң?

— Аны белгәннән сиңа җиңелрәк булырмы? — диде Атос.

— Дөресен әйтим: мин дә Портос сүзенә кушылам,— диде Арамис.

— Ә король сезгә отчет бирергә тиешме соң? Юк бит. Ул сезгә туп-туры әйтә: әфәнделәр, Гасконьда я булмаса Фландриядә сугыша башлаганнар — барыгыз, сугышыгыз, ди. Шуннан соң китәсез. Нәрсә хакына? Сез аныисын хәтта уегызга да китермисез.

— Д'Артаньянның әйткәне хак,— диде Атос.— Менә безгә ял бирелү турында де Тревиль әфәнде җибәргән өч таныклык, менә кем биргәнлеге билгесез булган өч йөз пистоль акча. Кая җибәрсәләр, шунда үләргә китәбез. Җан бәһасе ул кадәр үк төпченүгә бәрабәр микән?! Д'Артаньян, мин синең белән китәргә әзермен.

— Мин дә әзер! — диде Портос.

— Мин дә! — диде Арамис та.— Китү дигәннән, мин хәзер Париждан китәргә бик ризамын, миңа бераз күңелне ачарга кирәк.

— Бер дә борчылмагыз, әфәнделәр, күңелегезне ачарлык хәлләр булыр,— дип өстәде д'Артаньян.

— Алайса, бик шәп. Кайчан кузгалабыз? — дип сорады Атос.

— Хәзер үк кузгалабыз. Бер генә минутны да әрәм итәргә ярамый,— диде д'Артаньян.

— Әй, Гримо, Планше, Мушкетон, Базен! — дип дүртесе берьюлы хезмәтчеләренә кычкырдылар.— Ботфортларыбызны майлагыз, атларыбызны китерегез.

Ул заманда һәр мушкетер үзенең төп квартирында, казармадагы кебек, үзе һәм хезмәтчесе өчен ат тотарга тиеш булган. Планше, Гримо, Мушкетон һәм Базен йөгерешеп хуҗалары боерганны үтәргә керештеләр.

— Хәзер инде кампаниянең планын төзик. Иң элек без кая таба юл тотабыз? — диде Портос.

— Калега. Лондонга иң якын юл шуннан,— диде д'Артаньян.

— Ул чагында минем фикер мондый...— дип сүзгә керреште Портос.

— Сөйлә.

— Дүрт кешенең бергәләп каядыр баруы шик тудыруы мөмкин. Д'Артаньян безнең һәркайсыбызга тиешле күрсәтмәләрен бирер. Мин юлны тикшерү өчен иң алдан Булоньга чыгып китәм. Атос, ике сәгатькә кичегеп, Амьен аша китәр. Арамис безнең арттан Нуайонга юл тотар. Д'Артаньянга килсәк, ул теләсә кайсы юл белән китә ала, әмма ул Планше киемен кисен, ә Планше, гвардияче киемендә, д'Артаньян булып, аның артыннан китәр.

— Әфәнделәр, мондый эшкә хезмәтчеләрне дә катнаштырырга кирәк дип санамыйм мин. Дворян серне очраклы рәвештә

ычкындырса ычкындырыр, әмма лакей аны сатмый калмый,— диде Атос.

— Минемчә, Портосның планы уңышлы түгел,— диде д'Артаньян.— Иң элек, сезгә нинди күрсәтмәләр бирергә тиешлегемне мин үзем дә белмим. Мин хат илтәм. Менә шул. Мин ул хатны тагын өч данә итеп күчереп яза алмыйм, чөнки ул хат печәтләп ябыштырылган. Шуңа күрә, минемчә, безгә бергәләп хәрәкәт итәргә кирәк. Хат менә монда, шушы кесәдә,— дип, д'Артаньян хатның кайсы кесәсендә икәнлеген күрсәтте.— Әгәр дә мәгәр мине үтерсәләр, берегез хатны алып юлны дәвам иттерер. Аны да үтерсәләр, чират өченче кешегә кала һәм башкалар. Берәү булса да барып ирешсен. Шул җиткән.

— Браво, д'Артаньян! Мин дә нәкъ синеңчә уйлыйм,— диде Атос.— Өстәвенә, сүзебездә эзлекле булырга кирәк. Мин шифалы су белән дәваланырга барам, ә сез мине озата барасыз. Мин, Форж суына китмичә, диңгез буена барам — минем үзем теләгәнчә сайларга хакым бар бит. Безне тоткарларга маташырлар. Мин де Тревиль әфәнденең хатын чыгарып күрсәтәм, ә сез — үзегезнең таныклыгыгызны. Безгә һөҗүм итәләр. Без каршы сугышабыз. Безне хөкемгә тарталар, ә без, бер-ике тапкыр диңгезгә чумып чыгарга уйлаган идек, диюдән башканы белмибез. Аерым-аерым юлга чыккан дүрт кешене җиңүе берни түгел, ә менә бергә тупланган дүрт кеше инде ул — бер отряд була. Дүрт хезмәтчебезне дә пистолет һәм мушкетлар белән коралландырабыз. Безгә каршы армия җибәрсәләр дә сугышачакбыз, исән калганыбыз, д'Артаньян әйтмешли, хатны тиешле җиренә илтеп җиткерәчәк.

— Бик шәп,— диде Арамис.— Син, Атос, бик сирәк сөйлисең, әмма сөйли башласаң, Иоанн Остадан бер дә ким сөйләмисең. Мин Атосның планын кабул итәм. Ә син, Портос?

— Д'Артаньян риза булса, мин дә кабул итәм,— диде Портос.— Хат д'Артаньянга тапшырылган, шулай булгач, ул безнең экспедициянең башлыгы. Ул хәл итсен, без фәкать аның боерыгын үтәүчеләр генә.

— Алайса болай,— диде д'Артаньян,— мин хәл иттем: Атос әйткән планны кабул итәбез һәм ярты сәгатьтән юлга чыгабыз.

— Кабул иттек! — диде өч мушкетер өчесе беравыздан.

Шуннан соң һәркайсы янчыкка тыгылып, җитмеш бишәр пистоль акча алды да, ярты сәгатьтән юлга әзер булу өчен, җыенырга керешә.

## XX

## *СӘЯХӘТ*

Мажара эзләүче дүрт егетебез төнге сәгать икедә Сен-Дени капкасы аша Париждан чыгып киттеләр. Тирә-юнь дөм-караңгы булганлыктан, сөйләшми генә бардылар; төн караңгысы их-

тыярсыздан күңелгә шик-шом сала — бөтен җирдә аларны сагалап торалардыр кебек тоела иде.

Таң атып, офыктан кояш нурлары сирпелә башлау белән аларның телләре чишелде, кояш чыгып житү белән гадәттәге күңел көрлеге дә кайтты. Сугышка керергә җыенгандагы кебек, йөрәкләре дөп-дөп тибә, күзләре елмая. Гомернең киселү куркынычы булса да, яшәү дигәнең асылда алай бигүк начар нәрсә түгел сыман тоела иде.

Хәер, читтән карагайда алар колоннасы да ярыйсы гына җилле күренә: кара атларга атланган мушкетерлар, атларның нык-нык басып атлап килүләре — бу турылыклы солдат дусларының эскадронда өйрәнгән гадәтләре буенча тигез адым белән хәрәкәт итүләре — болар барысы үзләре генә дә иң яшерен, иң серле эшне дә фаш итүе ихтимал иде.

Дүрт дустан арттарак баштанаяк коралланган хезмәтчеләре килә.

Шантильига чаклы ул-бу булмады. Бирегә дуслар иртәнге сәгать сигездә килеп җиттеләр. Тамак ялгап аласылары бар иде. Вывескасына ярты плащын бер хәерчегә бирүче изге Мартин сурәте ясалган трактир янында атларыннан төштеләр. Хезмәтчеләренә, шундук юлга чыгарга әзер булып тору өчен, атларның иярен салдырмаска куштылар.

Дүрт дус тулай бүлмәгә кереп, өстәл янына утырыштылар. Шул ук өстәлдә әлерәк кенә Даммартен юлыннан килгән бер дворян да ашап утыра иде. Ул һавалар турында сүз башлады. Безнең юлчылар аңа җавап бирделәр. Дворян алар исәнлегенә шәраб эчте. Болар аның исәнлегенә эчтеләр.

Әмма Мушкетон кереп атларның әзер икәнлеген әйтүгә, дүрт дус өстәл яныннан кузгала башлагач, ят кеше Портоска кардинал исәнлеге өчен шәраб эчәргә тәкъдим ясады. Портос, әгәр сез үз нәүбәтегездә король исәнлегенә эчсәгез, мин әзермен, дип җавап кайтарды. Ят кеше, мин кардинал хәзрәтләреннән башка корольне белмим, диде. Портос аны исерек баш дип атады. Шуннан соң ят кеше кылычын суырып чыгарды.

— Сез акылсызлык эшләдегез. Ләкин берни дә кылып булмый: хәзер инде чигенергә соң, бу кешене дөмектерегез дә тизрәк безне куып җитәргә тырышыгыз,— диде Атос.

Шуннан соң өч дус атларына атландылар да җан-фәрманга чаптырып китеп бардылар, Портос исә дошманы алдында, мин сезне кылыч белән сугышу сәнгатендәге барлык ысулларны кулланып тишкәләп бетерәчәкмен, дип ант итте.

Биш йөз адым чамасы җир киткәч, Атос:

— Шулай итеп, беренчесе булды,— дип куйды.

— Нишләп ул кеше Портоска бәйләнде соң әле, нигә башкабызга түгел? — дип сорады Арамис.

— Чөнки Портос башкаларыбыздан катырак кычкырып сөйләште. Шуңа күрә теге кеше аны безнең башлыгыбыз дип уйлады,— диде д'Артаньян.

— Бу Гасконь егете — акыл капчыгыдыр дип, мин һәрвакыт әйтә киләм,— дип сөйләнеп куйды Атос.

Шул рәвешчә алар юлларын дәвам иттерделәр.

Боведа, атлар бераз хәл алсын дип, аннары Портос та килеп житмәсме дип, ике сәгатькә ялга туктадылар. Ике сәгать узгач, Портосның килмәвен һәм аның хәбәр-хәтере дә булмавын күреп, тагы юлга кузгалдылар.

Боведан чыгып, бер миль чамасы киткәч, юл тар гына бер аралыктан узган төштә, аларга тугыз-ун кеше очрады. Бу кешеләр, биредә юлга таш җәелмәгән булуыннан файдаланып, аны төзәткән булып маташалар, чынлыкта исә чокырлар казып, балчыктагы тәгәрмәч эзләрен тагы да тирәнәйтергә генә тырышалар иде.

Арамис, бу ясалма баткаклыкка кереп ботфортларын пычратудан куркып, тегеләргә усал гына кычкырып эндәште. Атос аны тыеп калмакчы булган иде дә, тик эш узган иде инде. Эшчеләр юлчыларны мыскыллап көләргә керештеләр. Аларның шулкадәр оятсыз рәвештә мыскыл итүләре хәтта авыр сабырлы Атосны да чыгырыннан чыгарып берсенең өстенә аты белән барырга мәҗбүр итте.

Шуннан соң әлеге кешеләр канауга төштеләр дә яшереп куйган мушкетларын алдылар. Безнең җиде юлчыбызга кораллы кешеләр сафы аша ерып дигәндәй узарга туры килде. Арамис кулбашына пуля тиеп яраланды, ә Мушкетонның билдән түбәнрәк йомшак җиренә пуля керде. Бары тик Мушкетон гына атыннан төште: ярасын карап күрә алмагач, ул чынлыктагыдан авыррак дип уйлады, күрәсең.

— Засада бу! Атышып маташмыйбыз! Алга! — диде д'Артаньян.

Арамис, яраланган булса да, атының ялына ябышып, башкалар артыннан чапты. Мушкетон аты аларны куып житеп, җайдагыннан башка гына, үз урынына басты.

— Запас атыбыз булыр,— диде Атос.

— Запас эшләпә булуны кирәгрәк саныйм мин,— диде аның сүзенә каршы д'Артаньян.— Минем эшләпәмне пуля очыртып төшерде. Ярый әле, шунысы бәхет: теге хатны эшләпә эченә яшермәгәнмен!

— Анысы шулаен шулай, ә менә бичара Портосны моннан узган чагында үтерәчәкләр бит,— диде Арамис.

— Портос аягында басып тора алырлык хәлдә булса, безне әллә кайчан куып житкән булыр иде инде,— диде Атос.— Минемчә, теге исерек баш кара-каршы басу белән айнып киткәндер.

Юлчылар тагын ике сәгать чамасы атларын чаптырдылар. Атлар инде тәмам өшәнгән — озакламый хәлдән таеп егылу куркынычы да бар иде.

Алар, сагалап торучыларга очрау ихтималы азрак булыр дип, кечерәк юлга төштеләр. Әмма Кревкерга житкәч, Арамис,

минем бүтән барырлык хәлем калмады, диде. Чыннан да, бирегә кадәр килеп җитү өчен аңа, тыштан бик нәфис булып, үзен нәзакәтле тотса да, бөтен чыдамлыгын-түземен җигәргә туры килде. Чырае аның агарганнан-агара бара иде, ияреннән егылып төшмәсен өчен аны тотып барырга кирәк була башлады. Шуңа күрә Арамисны бер кабак ишеге төбендә атыннан төшереп, янында Базенны калдырдылар — кораллы бәрелеш вакытында аңысы ярдәм итүдән бигрәк комачау гына булачак иде. Шуннан соң башкалары, Амьенда төн кунарга исәпләп, тагын кузгалып киттеләр.

Ике галиҗәнап һәм аларның ике хезмәтчесе Гримо белән Платшедан гыйбарәт булган кечкенә генә отряд янә юлдан җилдереп бара башлагач, Атос әйтә куйды:

— Шайтаным! Моннан ары мин аларның тозагына эләкмәячәкмен. Ант итеп әйтәм: шушыннан Калега барып җиткәнче авызымны да ачтыра алмаячаклар. Валлаһи...

— Ант итмә... Иң яхшысы — атларның түзәрлек чамасы булса, кызурак җилдерик,— диде д'Артаньян, аны сүзеннән бүлдереп.

Юлчылар шпорлары белән атларның янтауларына тибеп алуга, атларга яңа көч һәм дәрт өстәлгән кебек булды. Алар төн уртасында Амьенга җитеп, «Алтын Лалә» кунакханәсенең ишеге төбендә атларыннан төштеләр.

Трактир хуҗасы дөньяда иң алчак, иң кунакчыл бер кеше булып күренде. Ул, бер кулына шәм, икенчесенә төнге башлыгын тотып, кунакларны каршы алды. Ике кунагына аерым-аерым бик шәп ике бүлмә бирергә нияте барлыгын белдерде. Тик, кызганычка каршы, бүлмәләр икесе кунакханәнең ике башында икән. Д'Артаньян белән Атос ул бүлмәләрдән баш тарттылар. Трактир хуҗасы, сез галиҗәнапларга ярардай башка бүлмәм юк шул, дип җавап кайтарды, моңа каршы юлчылар, тулай бүлмәдә идәнгә матрас җәеп кенә йокларбыз, диделәр. Трактир хуҗасы үз дигәненчә эшләмәкче булса да, юлчылар күнмәде. Алар теләгенә буйсынырга туры килде.

Д'Артаньян белән Атос урыннарын җәеп, ишекне бикләргә дә өлгермәделәр — ишегалды ягыннан тәрәзә капкачын шакыдылар. «Кем ул?» дип сорагач, хезмәтчеләренең тавышын танып, тәрәзәне ачтылар.

Чыннан да, Планше белән Гримо иде болар.

— Атларны Гримо үзе генә дә саклар,— диде Планше.— Хуҗа әфәнделәр рөхсәт итсә, мин шушында ишеккә аркылы ятам. Шуннан соң инде галиҗәнаплар, безгә тия алмаслар дип, тынычлап йокларлар.

— Нәрсәгә ятмакчы буласың соң? — дип сорады д'Артаньян.

— Әнә минем түшәк,— диде Планше, бер кочак салам күрсәтеп.

— Сүзең хак, кер монда,— диде д'Артаньян.— Хуҗаның кыяфәте миңа да бик ошап бетмәде: артык төче күренә.

— Миңа да ошамый,— дип җөпләде Атос.

Планше тәрәзәдән кереп, ишеккә аркылы ятты. Гримо исә, иртәгә иртәнгә сәгать бишкә атлар барысы әзер булып торыр дип, абзарга йокларга китте.

Төн ярыйсы гына тыныч узды. Дөрес, төнге икеләр тирәсендә кемдер берәү ишекне ачмакчы булып маташты, тик Планше уянып: «Кем ул?» — дип кычкыргач, тыштан: «Ишекне ялгыштырганбыз»,— дип китеп бардылар.

Иртәнге сәгать дүрттә абзардан ачы бер аваз ишетелде. Гримо ат караучыларны уятырга керешкән булган да тегеләр торып аны тукмый башлаганнар икән. Ике дус, тәрәзәне ачып карагач, бичара Гримоның һуштан язып ишегалдында егылып ятуын күрделәр. Аның башын сәнәк сабы белән бәреп ярганнар иде.

Планше, атларны иярләргә дип, ишегалдына төште, ләкин атларның аякларын имгәткәннәр булып чыкты. Узган көнне биш-алты сәгать җайдаксыз килгән Мушкетон аты гына юлга чыгарлык, ләкин, ни хикмәттер, хуҗаның бер атыннан кан алырга чакырылган имче, ялгышып, Мушкетон атыннан кан агызган, имеш.

Күңелләргә шом керә башлады: әнә шулай бер-бер артлы бәла-каза килеп торуы очраклылык аркасында да һәм шул ук дәрәҗәдә мәкер белән башкарылган эшнең нәтиҗәсе булуы да ихтимал иде. Атос белән д'Артаньян урамга чыктылар, ә Планше якын-тирәдә сатлык өч ат табып булмасмы дип белешергә китте. Трактир ишеге төбендә авызлыклаган-иярләгән, ял иткән таза ике ат тора иде. Нәкъ аларга кирәкле атлар иде болар. Планше атларның хуҗалары кайдалыгын сорады. Хуҗалары биредә кунакханәдә кундылар, хәзер трактирчыга акча түлиләр, дип җавап бирделәр аңа.

Куньш чыккан өчен акча түләргә дип Атос та аска төшеп китте, д'Артаньян белән Планше ишек төбендә басып калдылар.

Трактирчы өйнең түрендәге тәбәнәк түшәмле бүлмәдә икән— Атоска шунда узарга куштылар.

Атос, аны-моны уена да китермичә, бүлмәгә барып керде һәм ике пистоль акча чыгарып хуҗага бирде. Трактирчы сөзәк өсле биек өстәл артында утыра, өстәленең бер тартмасы тартып чыгарып куелган иде. Ул акчаларны алды да, әйләндергәләп карагач, көтмәгәндә кычкырып җибәрде: ялган тәңкәләр болар, диде, Атос белән аның иптәшләре ялган акча ясаучылар, янәсе, мин сезне хәзер үк кулга алдыртам, диде.

— Ах, кабахәт җан! Мин синең колакларыңны чабып өзәм! — диде Атос аның өстенә килә башлап.

Шул минутта ук ян ишектән баштанаяк коралланган дүрт ир атылып кереп Атоска ташландылар.

— Мин тозакка эләктем! Бар, чап, д'Артаньян! Шпорла! —

дип ачы аваз белән кычкырды Атос һәм шарт-шорт китереп ике тапкыр пистолетыннан атты.

Д'Артаньян белән Планше кыстатып тормадылар. Ишек төбендәге атларны чишеп, атланып алдылар да шпорлый-шпорлый җан-фәрманга чаптырып киттеләр.

— Атоска ни булганын күрмәдеңме син? — дип сорады д'Артаньян Планшедан, җилдереп барган шәпкә.

— Һай, әфәндем, мин аның үзенә ташланган ике кешене атып екканын күрдем, аннары ишек пыяласы аша калганнары белән кылычка-кылыч сугыша кебек күземә чагылды.

— Чын егет икәнсең, Атос! — дип пышылдап әйтеп куйды д'Артаньян.— Тик шунысы гына бик начар булды — аны ташлап китәргә туры килде! Хәер, берничә адымнан безне дә шундый ук язмыш көтүе ихтимал. Алга, Планше, алга! Бик шәп егет бит син.

— Пикардия егетен тора-бара гына белеп җиткерерсез әле дип әйткән идем бит мин сезгә, әфәндем. Өстәвенә, хәзер мин — туган ягымда, ә туган ягымда булу минем җаныма рух бирә,— дип җавап кайтарды Планше.

Икәүләшеп атларын тагын да катырак шпорлый-шпорлый, беркая тукталмастан, Сент-Омерга хәтле чаптырып бардылар. Сент-Омерда атларын бераз ял иттерделәр, тик, тагын бер-бер хәл килеп чыкмагае дип, тезгенне кулдан ычкындырмадылар һәм, шунда аяк өсли генә капкалап алып, тагы атларын кудылар.

Кале капкасына җитәргә йөз адым чамасы кала д'Артаньянның аты гөрселдәп җиргә ауды, аны инде янадан торгызырлык түгел: борын тишекләреннән һәм күзләреннән шыбырдап кан ага иде. Бары тик Планше аты гына аягында басып тора иде, ләкин ул ат та туктады, аны да урыныннан кузгатып булмады.

Бәхеткә каршы, әйткәнебезчә, калага килеп җитәргә йөз адым чамасы гына калган иде. Атларын юл буенда калдырып, алар гаваньга йөгерделәр. Планше д'Артаньянны ниндидер бер дворянга игътибар иттерде. Бу кеше дә әле генә хезмәтчесе белән бирегә килеп җиткән иде булса кирәк — алардан нибары илле адым чамасы алдарак шул ук якка бара иде.

Каядыр ашыккан әлеге дворянны куып җитү өчен алар кызурак атладылар. Дворян дигәнебезнең ботфортларына бер карыш тузан утырган иде. Көймәләр янына килеп җитү белән ул, хәзер үк Англиягә чыгып булмасмы? — дип сорашырга керешә.

Кузгалып китәргә әзер булып торган бер көймәнең хуҗасы:

— Анда чыгуы берни түгел дә, тик менә бүген иртән кардиналның махсус рөхсәтеннән башка беркемне дә чыгармаска дигән боерык килде шул,— дип җавап бирде.

— Минем андый рөхсәтем бар. Менә ул,— диде дворян кесәсеннән кәгазь чыгарып.

— Порт башлыгыннан тамга салдырып килегез. Аннары минекеннән башка көймә эзләмәгез,— диде көймә хуҗасы.

— Порт башлыгын кайдан табып була соң?

— Ул үзенең кала читендәге йортында.

— Ул йорт моннан еракмы?

— Каладан чирек миль чамасы. Әнә, күренеп үк тора, әнә теге калку итәгендә.

— Яхшы,— диде дворян.

Һәм хезмәтчесен ияртеп, порт башлыгының йортына китте. Д'Артаньян белән Планше, аларны биш йөз адым чамасы алгарак җибәреп, үзләре алар артыннан иярделәр.

Каладан чыккач, д'Артаньян адымын кызулый төште, әлеге дворянны кечерәк бер әрәмәлек читендә куып җитте.

— Эфәндем, сез бик ашыгасыз бугай? — дип сүз башлады д'Артаньян.

— Ашыгам шул, эфәндем.

— Бик кызганыч икән,— диде д'Артаньян,— мин үзем дә бик ашыкканлыктан, сезгә бер үтенечем бар иде.

— Нинди үтенеч?

— Мине алданрак җибәрмәссезме дигән идем.

— Булмый, эфәндем,— диде дворян.— Кырык дүрт сәгать эчендә алтмыш миль юл килдем, миңа иртәгә төш вакытында Лондонда булырга кирәк,— диде дворян.

— Ә мин шул ук юлны кырык сәгатьтә килеп җиттем һәм иртәгә иртәнге сәгать унда миңа да Лондонда булырга кирәк.

— Анысы бик кызганыч икән, эфәндем, әмма мин беренче булып килеп җиттем шул, икенче булып китәргә җыенмыйм.

— Анысы да бик кызганыч, эфәндем, әмма мин икенче булып килеп җитсәм дә, беренче булып китәм.

— Король әмере белән барам! — дип кычкырды дворян.

— Мин үз теләгем белән! — диде д'Артаньян.

— Әллә сез талашырга сәбәп эзлисезме?

— Әлбәттә!

— Ни кирәк сезгә?

— Беләсегез киләме?

— Әлбәттә.

— Беләсегез килсә, менә шул: сездә бер боерык бар, миңа бик кирәк булса да, ул нәрсә миндә юк. Миңа әнә шул боерык кирәк.

— Шаяртасыздыр сез?

— Юк, мин беркайчан да шаярып сөйләшмим.

— Җибәрегез мине!

— Җибәрмим!

— Батыр егет, мин сезнең башыгызны бетерәм бит! Любен! Пистолетлар!

— Планше, хезмәтчесе белән эшне бетер, ә мин — хуҗасы белән,— диде д'Артаньян.

Беренче каһарманлыкларыннан соң батырланып киткән

Планше Любенга ташланды да, көчлерәк һәм чаярак булганлыктан, тегене егып салып, күкрәгенә тезе белән басты.

— Мин үз эшемне эшләдем, әфәндем, сез дә үзегезнекен эшләгез! — дип кычкырды Планше.

Дворян кеше, бу хәлне күреп, кылычын суырып чыгарды да д'Артаньянга ташланды. Әмма аның каршында көчле дошманы басып тора иде шул.

Д'Артаньян өч секунд эчендә аны өч тапкыр яралады, кылычы белән кадаган саен:

— Менә монысы Атос өчен! Монысы Портос өчен! Менә монысы Арамис өчен! — дип сөйләнде.

Өченче кадавында дворян көлтә шикелле савылып җиргә ауды.

Д'Артаньян, аны үлгән дип, һич югы аңын җуйган дип уйлап, якынрак килде дә теге боерыкны алмакчы булды. Аны тентим дип кулын сузуга, яралы дворян кулындагы кылычы белән егетнең күкрәгенә кадады.

— Менә монысы сезнең өчен! — дип сөйләнде үзе.

Д'Артаньян ярсып китеп:

— Ә менә монысы үзем өчен! Соңгысы закускага! — диде дә тегене, корсагына кадап, җиргә кадаклап куйды.

Бу юлы инде дворян күзен йомды, аңын җуйды.

Д'Артаньян, аның кесәсен капшап, рөхсәт кәгазен табып алды. Рөхсәт кәгазе граф де Вард исеменә язылган иде.

Егерме яшьләр чамасындагы аңын җуеп яткан,— ихтимал, җансыз уктыр,— яшь, чибәр бер ир-егеткә соңгы тапкыр карап алгач, д'Артаньян үзләренә бөтенләй чит-ят булган, хәтта аларның дөньяда барлыгын да белмәгән өченче кешеләр мәнфәгате өчен язмышның кешеләрне бер-берсен үтерергә мәҗбүр итүе турында уйлап авыр сулап куйды.

Ләкин озакламый бу уйларыннан аны Любен бүлдерде — ул ярдәмгә кешеләр чакырып каравыл салып акыра башлады.

Планше аны бугазыннан тотып кысып алды.

— Әфәндем, мин менә шушылай тотып торсам, аның тавышы чыкмас. Җибәрсәм, тагын акыра башлар. Нормандия егете бу, ә нормандлылар — бик үз сүзле халык,— диде Планше.

Чыннан да, Планше аның бугазын никадәр генә каты кысарга тырышмасын, Любен һаман да кычкырырга азапланып маташты.

— Туктале,— диде д'Артаньян.

Кесәсеннән яулык чыгарып, бу кире беткәннең авызына йомарлап тыкты.

— Ә хәзер аны агачка бәйләп калдырыйк,— диде Планше.

Алар аны бик әйбәтләп агачка бәйләделәр дә граф де Вардны өстерәп китереп хезмәтчесе янына якынрак куйдылар.

Төн җитте. Яралы дворян белән аягы-кулы бәйләүле хезмәтчесе юлдан бер читтә куак арасында иде, шуңа күрә аларның иртәнгә чаклы шунда ятачаклары тәгаен иде.

— Ә хәзер порт башлыгы янына киттек! — диде д'Артаньян.
— Сез яралангансыз түгелме? — диде Планше.
— Әллә ни юк. Иң элек иң ашыгыч эшне эшлик, яраны соңыннан карарбыз: минемчә, әллә ни куркыныч түгел шикелле.
Шуннан алар тиз-тиз атлап мөхтәрәм чиновник йортына таба киттеләр.
Аңа граф де Вард килгәнлеген әйттеләр.
Д'Артаньянны кабинетка керттеләр.
— Кардинал кул куйган рөхсәт кәгазегез бармы сезнең? — дип сорады порт башлыгы.
— Бар, әфәндем, менә ул, — диде д'Артаньян.
— Ярый, рөхсәт кәгазегезнең бөтен җире дөрес. Хәтта болышлык итәргә дигән күрсәтмәсе дә бар.
— Анысы бик табигый, чөнки мин кардинал хәзрәтләренең якын кешеләреннән берсе булам, — дип куйды д'Артаньян.
— Кардинал хәзрәтләре кемгәдер Англиягә чыгарга комачаулык итмәкче була ахры.
— Әйе, д'Артаньян дигән берәүгә; Беарн дворяны ул, Лондонга бару нияте белән, өч дустын ияртеп Париждан чыгып киткән.
— Сез аны беләсезме?
— Кемне?
— Шул д'Артаньянны?
— Бик яхшы беләм.
— Ул чагында сез миңа аның төсмерләрен әйтегез әле.
— Рәхәтләнеп әйтәм.
Шуннан соң д'Артаньян граф де Вардның төс-кыяфәтен тәфсилләп сөйләп бирде.
— Аны кем озата килә?
— Любен исемле лакее.
— Без аларны күздән ычкындырмабыз, безнең кулга гына килеп эләксеннәр, кардинал хәзрәтләре бер дә борчылмасын: без аларны каты сак астында Парижга кире озатырбыз.
— Һәм шул хезмәтегез белән кардиналның илтифатын казанырсыз, — диде д'Артаньян.
— Сез кайткач аны күрәсезме, граф?
— Әлбәттә.
— Сез аңа әйтегез: мин аның тугры хезмәтчесе.
— Һичшиксез, әйтермен.
Порт башлыгы, аның бу вәгъдәсенә бик сөенеп, рөхсәт кәгазенә тамга салды да д'Артаньянга кайтарып бирде.
Д'Артаньян артык сүз куертып тормады. Порт башлыгы белән баш иеп кенә саубуллашты да, рәхмәт әйтеп, чыгып китте.
Юлга чыккач, алар Планше белән кызурак атлап әйләнечтән урманны урап уздылар да калага икенче капкадан барып керделәр.

Теге көймә, кузгалырга әзер булып, һаман шунда тора. Хуҗасы ярда көтеп тора иде.

— Эшләр ничек? — дип сорады ул, д'Артаньянны күргәч.

— Менә минем рөхсәт кәгазе, порт башлыгы кул куйган.

— Ә икенче галиҗәнап?

— Бүген бармый ул,— диде д'Артаньян.— Бер дә борчылмагыз: мин икебез өчен дә юл хакын түләрмен.

— Алайса кузгалдык! — диде көймә хуҗасы.

— Кузгалдык! — дип җөпләде д'Артаньян.

Алар Планше белән көймәгә кереп утырдылар. Биш минуттан инде кузгалып киттеләр.

Нәкъ вакытында китеп өлгерде алар. Ярдан ярты миль чамасы ераклашкач, д'Артаньян ярда ут бөркелгәнен күрде, аннары гөрселдәгән тавыш та ишетелде.

Портның ябылуын белгертеп туптан аттылар.

Хәзер инде яраны карарга да вакыт иде.

Бәхеткә каршы, ярасы, нәкъ д'Артаньян уйлаганча, ул кадәр куркыныч түгел икән. Кылыч очы аның кабыргасына төртелеп, сөяк буйлап шуып кына киткән. Күлмәге шундук ярасына ябышкан да берничә тамчы гына кан аккан иде.

Д'Артаньян инде үзе тәмам арган-талган иде. Палубага салам түшәк җәеп биргәч, шунда яту белән йокыга талды.

Иртәгесе көнне таң аткан чакта Англия ярына барып җитәргә нибары өч-дүрт кенә миль калган иде инде. Төн буе әкрен җил искән, көймә дә шактый акрын хәрәкәт иткән иде.

Сәгать унда көймә Дувр портына кереп якорь ташлады. Унберенче яртыда д'Артаньян Англия җиренә төшеп аяк басты да:

— Килеп җиттек! — дип кычкырды.

Ләкин әле моның белән генә эш бетмәгән: Лондонның үзенә барып җитәсе бар иде.

Англиядә почта әйбәт эшли икән. Д'Артаньян белән Планше берәр ат алдылар. Почтальон атын алдан юрттырды. Дүрт сәгать дигәндә алар башкаланың капкасы төбенә килеп җиттеләр.

Д'Артаньян Лондонны белми, инглизчә дә бер авыз сүз белми иде. Шулай да кәгазь кисәгенә герцог Бекингэмның исемен язгач, герцог сараен бик тиз күрсәттеләр аңа.

Д'Артаньян герцогны барлык сәяхәтләрендә озатып йөри һәм французча бик шәп сөйләшә белә торган ышанычлы камердинерын чакыртып чыгарды. Гасконь егете аңа әле яңа гына бик мөһим бер эш белән Париждан килүен һәм герцогны күреп сөйләшәсе барлыгын әйтте.

Д'Артаньянның чынлап сөйләшүен күреп, Патрик — министр хезмәтчесенең исеме шулай иде — аның сүзенә ышанмый булдыра алмады. Ике ат иярләтеп, гвардияче егетне үзе озата китте. Планшега килгәндә исә, ул бичара аты өстеннән төшергәндә ару-талудан тәмам агач шикелле каткан, ярым үле

хәлендә. Д'Артаньян исә гади бер кеше түгел, тимердер кебек иде.

Виндзор замогына килеп җиткәч, алар герцогның кайда икәнен сорадылар. Король белән герцог Бекингэм моннан икеөч миль чамасындагы бер сазлыкка лачын белән ауга киткәннәр икән.

Бер егерме минуттан д'Артаньян белән юлдашы әйтелгән төшкә барып та җиттеләр. Озакламый Патрик герцогның лачын чакырган тавышын ишетте.

— Милорд герцогка үзен кем чакыра дип әйтергә? — дип сорады Патрик.

— Самаритянка каршындагы Яңа күпердә аның белән талашкан бер егет чакыра, дип әйтегез.

— Бик сәер рекомендация!

— Менә күрерсез: бик шәп рекомендация ул.

Патрик атын кушаяклатып чаптырып китте. Герцогны куып җитеп, югарыда әйтелгән рәвештә, үзен бер атчабар егет көткәнлеген хәбәр итте.

Герцог шундук бу егетнең д'Артаньян икәнлеген төшенеп алды һәм, Франциядә миңа килеп әйтерлек бер-бер хәл булган, күрәсең, дип уйлап, бу яңалыкны китерүче кешенең кайда икәнлеген генә сорады. Таныш гвардияче формасын ул ерактан ук күреп алды да атын кушаяклатып туп-туры д'Артаньянга таба чаптырып китте.

— Королевага берәр бәхетсезлек килдеме әллә? — дип кычкырып сорады герцог, һәм аның шушы бер соравыннан бөтен кайгыру-борчылуы, яратуы аңлашылды.

— Алай ук дип уйламыйм, шулай да королевага зур куркыныч килергә тора, ул куркынычтан аны фәкать сез галиҗәнап кына коткарсагыз коткара аласыз.

— Мин? — дип гаҗәпләнеп сорады герцог.— Минем дә аңа берәр файдам тияр микәнни? Мин дә андый бәхеткә ирешермен микәнни? Сөйләп бирегез! Тизрәк сөйләгез!

— Менә хат,— диде д'Артаньян.

— Хат? Кемнән?

— Королевадан дип уйлыйм.

— Королевадан? — дип кайтарып сорады герцог. Д'Артаньян, аның йөзе көл төсле агарып китүкәнлеген күреп, бер-бер хәл булдымы әллә монда, дип уйлады.

Герцог конвертны ачты. Хатның утәли тишелгән бер урынын күрсәтеп, д'Артаньяннан:

— Нәрсә бу? — дип сорады.

— Ах, мин аны күрмәгәнмен,— диде д'Артаньян.— Граф де Вард кылычы белән күкрәгемә кадаганда тишкән аны.

— Яралагандыгызмыни сез? — дип сорады герцог, хатны ача-ача.

— Әллә нәрсәсе юк, бераз тырналган гына,— диде д'Артаньян.

— Ай тәңрем! Ниләр ишетәм мин! — дип куйды герцог.— Патрик, биредә торып тор, юк, кайда гына булмасын — корольне эзләп тап та әйт: галиҗәнапның мине гафу итүен бик үтенеп сорыйм. Гаять зарур бер эш мине Лондонга кайтып китәргә мәҗбүр итә. Киттек, әфәндем, киттек!

Һәм шуннан соң алар атларын җан-фәрманга чаптырып башкалага таба киттеләр.

## XXI

## ГРАФИНЯ ВИНТЕР

Юлда кайткан чакларында герцог, д'Артаньяннан бөтен хәлне сорашмаса да, д'Артаньян белгән кадәресен барысын да төпчеңде. Егет авызыннан ишеткәннәрне үз хәтерендәгеләр белән чагыштырып карагач, герцог Бекингэм хәлне билгеле бер дәрәҗәдә күз алдына китерде. Хәер, королеваның аңлашылып бетми торган бик кыска хаты да хәлнең җитди икәнлеген әйтеп тора иде. Ләкин герцогны бигрәк тә гаҗәпкә калдырганы шул булды: кардинал егетне никадәр генә Англия җиренә аяк бастырмаска тырышса да, аны юлда тоткарлап кала алмаган иде. Герцогның бу гаҗәбенә каршы җавап итеп д'Артаньян үзенең нинди саклык чараларын күрүен һәм өч дустының фидакарьлеге аркасында (ул аларны яраланган, канга баткан хәлләрендә юлда ташлап китәргә мәҗбүр булган икән), үзенең җиңелчә кылыч ярасы белән генә котылып калуын сөйләде. Әнә шул кылыч инде королеваның хатын тишкән иде, шул кылыч өчен инде ул граф де Вардтан бик яман үч алды. Д'Артаньян бу хәлләрне гади генә бер нәрсә кебек итеп сөйләгән чагында герцог әледән-әле егеткә күз салгалады, әйтерсең ул егерме яше дә тулып җитмәгән бу егетнең шулкадәр сак-сизгер, батыр йөрәкле һәм турылыклы була алуына ышанып бетми иде.

Атлар җилдереп кенә чабып кайттылар һәм берничә минуттан инде алар Лондон капкасы төбенә килеп тә җиттеләр. Д'Артаньян, калага кергәч герцог атын тыя төшәр, дип уйлаган иде, әмма герцог атын җан-фәрманга чаптыра бирде, юлында туры килгән саксызрак кешеләрне бәреп егуына да исе китмәде. Эчке каладан узган чакта да берничә тапкыр шундый хәл булды, ләкин бәреп еккан кешесенә «ни булды?» дип башын да борып карамады. Тирә-яктан ләгънәт-каргыш сыман тавышлар ишетелеп торса да, д'Артаньян аның артыннан калмады.

Үз йортына кайтып кергәч, герцог атыннан сикереп төште дә, аңа бүтән әһәмият итмәстән, тезгенен ташлап тиз-тиз генә йөгерә-чаба баскычтан менеп китте. Д'Артаньян бу турылыклы, чыдам малкайларның хәле өчен беркадәр борчылып (ул инде аларның шәплеген күреп өлгергән иде) герцог артыннан

иярде. Сөенеченә каршы, ул кухня белән абзардан өч-дүрт хезмәтче йөгереп чыгып атларны алып китүләрен күреп калды.

Герцог шундый кызу атлый иде, д'Артаньян аның артыннан көчкә-көчкә җитеште. Франциядәге иң зур вельможаларның күз алдына да килмәслек итеп зиннәтләп җиһазлаган берничә кунак бүлмәсен узгач, ул, ниһаять, искиткеч бер зәвык һәм байлык өлгесе булырлык йокы бүлмәсенә килеп керде. Бүлмәнең түрдәге куышында стена тышламасы белән яртылаш капланган бер ишек беленеп тора иде. Герцог муенындагы алтын чылбырга таккан алтын ачкыч белән шул ишекне ачты.

Д'Артаньян әдәп йөзеннән бер читтәрәк туктап калды, ләкин герцог әлеге кадерле бүлмәнең бусагасында ук гвардияче егеткә борылып карады да аның тартынып торуын күргәч:

— Әйдәгез, әгәр олуг ханымны күрү бәхетенә ирешсәгез, күргәннәрегезнең барысын аңа сөйләп бирерсез,— диде.

Д'Артаньян, бу чакырудан кыюланып, герцог артыннан эчкә керде, артларыннан ишек ябылды.

Алар стеналары алтын укалы фарсы ефәге белән тышланган, бик күп шәм белән яктыртылган кечкенә генә часовняга килеп керделәр.

Михрап сыман нәрсәсе өстендә, түбәсенә кызыл һәм ак каурыйлар тотылган зиннәтле зәңгәр бәрхет чатыр астында Анна Австрияленең бөтен буена ясалган сурәте басып тора иде. Бу сурәт оригиналына шулкадәр дә охшаган иде — д'Артаньян сискәнеп китеп кычкырып җибәрә язды: королева телгә килеп сөйләшә башлар кебек иде.

Михрапта сурәт астында алсу тартма тора, ул тартмада теге асылташлар саклана иде.

Герцог, михрап янына килеп, кул-аяклары кадакланган Гайса пәйгамбәр каршындагы изге ата шикелле, идәнгә тезләнде, аннары тартманы ачты. Тартмадан елык-елык иткән асылташлы зур зәңгәр бант алып:

— Мәгез. Бәя биргесез кыйммәтле асылташлар менә шушы инде ул,— диде.— Үземне шушының белән бергә каберемә күмдерермен дип ант иткән идем. Миңа моны королева үзе бирде дә — үзе кире ала. Бер ходаның кодрәте кебек, һәр җирдә һәм һәр кайчан аның теләге яшәсен!

Шулай дигәч, герцог үзеннән китәсе асылташларны берәм-берәм үбәргә керешкте. Һәм көтелмәгәндә әллә нинди бер тавыш белән аһылдап кычкырып җибәрде.

— Нәрсә булды? — дип каушап-хафаланып сорады д'Артаньян.— Ни булды сезгә, милорд?

— Эш харап! — диде герцог, көл төсле агарынып.— Ике асылташы юкка чыккан. Ун гына калган.

— Милорд аларны югалтканмы яисә урлаткан дип уйлыймы?

— Урлаганнар, кардинал эше ул. Менә карагыз — таккан тасмаларын кайчы белән кискәннәр.

— Әгәр милорд кем урлаганлыгын белә алса... Шәт, ул асылташлар урлаган кешенең кулындадыр әле.

— Туктагыз әле! Туктагыз! — диде герцог.— Мин бу ташларны бер генә тапкыр тактым, моннан бер атна элек, король балында, Виндзорда. Графиня Винтер шул балда минем белән татулашырга тырышып карады — аңарчы безнең аралар бозылган иде. Көнче хатынның татулашырга тырышуы үзенчә үч алуы гына булган. Шул көннән соң ул минем күземә бүтән чалынмады. Ул хатын — кардиналның шымчысы.

— Аның шымчылары шулай бөтен дөньяга таралган микәнни? — дип сорады д'Артаньян.

— Әйе, әйе! — диде герцог, ярсудан тешен кысып.— Әйе, бик яман дошман ул. Ә теге бал кайсы көнгә билгеләнгән?

— Киләсе дүшәмбегә.

— Киләсе дүшәмбегә! Тагын биш көн вакыт бар икән әле, вакыт җитәрлек... Патрик! — дип кычкырды герцог, часовня ишеген ачып.

Ишектә герцогның камердинеры күренде.

— Ювелирым белән секретарьны китерт!

Камердинер, бер сүз әйтмичә, һичбер карышусыз буйсынгандагы бер тизлек белән китеп тә барды.

Беренче кеше итеп ювелирны чакырган булсалар да, иң элек секретарь килеп җитте. Болай булуы бик табигый, чөнки ул шушы йортның үзендә тора иде. Ул килгәндә Бекингэм йокы бүлмәсендә өстәл янында утыра: үз кулы белән ниндидер боерыклар яза иде.

— Джексон әфәнде,— дип эндәште герцог аңа,— сез хәзер үк лорд-канцлерга барып әйтегез: шушы боерыкларны үтәүне мин шәхсән аңа йөклим. Мин ул боерыкларның хәзер үк игълан ителгән булуын телим.

— Галиҗәнап,— диде секретарь, кәгазьгә тиз-тиз күз йөгертеп чыкканнан соң,— әгәр дә лорд-канцлер: «Мондый гадәттән тыш чаралар күрүнең сәбәбе нәрсә?» — дип сораса, мин ни дип җавап бирермен соң?

— Минем шулай теләвемне һәм кылган гамәлләрем өчен беркем каршында да җавап бирергә тиеш түгеллегемне әйтерсең.

— Әгәр дә мәгәр король галиҗәнаплары очраклы рәвештә генә ни өчен моннан соң бер корабның да Британия портларыннан чыгып китә алмавын белергә теләсә, лорд-канцлер аңа да шул җавапны әйтергә тиешме? — дип сорады секретарь көлемсерәп.

— Хак әйтәсез, әфәндем,— диде Бекингэм.— Ул чагында лорд-канцлер корольгә минем сугыш игълан итәргә карар кылуымны һәм бу чара — Франциягә каршы беренче дошманлык гамәле икәнен әйтсен.

Секретарь баш иеп чыгып китте.

— Бу як мәсьәләсендә без тыныч була алабыз,— диде герцог, д'Артаньянга таба борылып.— Асылташларны Франциягә чыгарып өлгермәгән булсалар, алар анда сездән соң гына кайтып җитәчәк.

— Ничек алай?

— Мин король портларындагы бөтен кораб-көймәләрне диңгезгә чыгудан тыю хакында әле хәзер генә боерык бирдем, махсус рөхсәттән башка ул корабларның берсе дә кузгалып китә алмый.

Король ышанычы белән тапшырылган чиксез властьны үз мәхәббәте өчен хезмәт иттерүче бу кешегә д'Артаньян исе китеп карап куйды. Герцог Гасконь егетенең чыраеннан аның ниләр уйлаганын сизенде дә, елмаеп:

— Әйе, шулай! — дип куйды.— Анна Австрияле — ул минем чын королевам; ул бер генә сүз әйтсен — мин илемә дә, королемә дә һәм динемә дә хыянәт итәргә әзермен. Мин Ларошельдәге протестантларга ярдәм итәм дип вәгъдә биргән идем, королева миннән аларга ярдәм итмәвемне сорады — мин буйсындым. Мин протестантларга биргән вәгъдәмне үтәмәдем, аның каруы — королеваның теләген үтәдем. Менә шуннан уйлап карагыз инде: мин үземнең тугрылыгымның әҗерен артыгы белән кайтармадыммыни? Мин бу тугрылыкка аның сурәте белән бурычлы бит!

Д'Артаньян халыкның язмышы һәм бик күп кешеләрнең гомере кайчак әнә шулай бик нечкә җептә генә асылынып торуын уйлап гаҗәпкә калды.

Егет шундый уйларына чумып уйланып торганда бүлмәгә ювелир килеп керде. Бу — ирландияле бер кеше, үз эшенең искиткеч зур остасы иде. Үзенең әйтүенә караганда, герцог Бекингэм заказларын үтәп, елына йөзәр мең фунт акча эшли икән.

— О'Рейли әфәнде,— диде герцог, аны часовняга алып кереп,— менә шушы асылташларны карап әйтегез әле: берсе-берсе ни хак тора шуларның?

Ювелир бер күз салу белән кысасының ни дәрәҗәдә нәфис эшләнгәнлеген бәяләде һәм асылташларының күпме торуын исәпләде дә бернинди икеләнүсез әйтте:

— Берсе-берсе меңәр ярым, милорд,— диде.

— Шушындый ике асылташ ясарга ничә көн кирәк булыр? Монда ике асылташ җитмәгәнлеген күрәсездер.

— Бер атна, милорд.

— Берсе-берсе өчен өчәр мең түлим — миңа берсекөнгә кирәк алар.

— Булыр, милорд.

— Искиткеч бер кеше сез, О'Рейли әфәнде. Тик моның белән генә бетмәде әле: бу асылташлар беркем кулына да ышанып тапшырыла алмый — аларны фәкать монда, сарайда гына ясарга кирәк.

— Алай булмый, милорд. Яңалары белән искеләре арасында аерма сизелмәслек итеп фәкать мин генә ясый алам аны.

— Алайса, О'Рейли әфәнде, сез минем тоткыным буласыз. Сез хәзер минем сарайдан чыгып китәргә теләсәгез дә чыга алмас идегез. Шулай булгач, сез бу хәлгә күнегез. Үзегезгә кирәк булачак ярдәмчеләрегезнең исемнәрен һәм алар алып килергә тиешле коралларны әйтегез.

Ювелир герцогның гадәт-холкын бик яхшы белә, шуңа күрә карышып маташу файдасыз икәнен аңлый иде. Бу мәҗбүрияткә ул шундук күнәргә тиеш булды.

— Хатыныма хәбәр итәргә рөхсәт булырмы? — дип сорады ул.

— О, сезгә аның белән хәтта күрешергә дә рөхсәтителәчәк, кадерле О'Рейли әфәндем. Бер дә борчылмагыз: сез каты тоткынлыкка дучар ителмәссез. Әмма һәрбер борчу-мәшәкатьнең әҗере дә була. Менә сезгә, китергән борчуларны оныттыру өчен, сөйләшенгән хакка өстәп тагын бер мең пистольлек чек.

Д'Артаньян, бу министрның кешеләр һәм миллионнар белән шулкадәр иркен эш итүенә шаккатып, һаман да зиһенен җыя алмыйча тора иде әле.

Ул арада ювелир, хатынына хат язып, шуңа бер мең пистольлек чек теркәде, шуның бәрабәренә иң оста ярдәмчесен, асылташлар, шулай ук үзенә кирәк булачак коралларын җибәрергә кушты, асылташларның үлчәвен һәм сыйфатын әйтергә дә онытмады.

Бекингэм ювелирны билгеләнгән бүлмәсенә илтте, барлыюклы ярты сәгать эчендә ул бүлмә мастерскойга әйләндерелде. Аннары герцог һәр ишек төбенә сак куярга кушып, үзенең камердинеры Патриктан башка беркемне дә бүлмәгә кертмәскә дип катгый боерык бирде. Ювелир О'Рейли белән аның ярдәмчесенә бернинди сәбәп белән дә бүлмәдән чыгып йөрергә рөхсәт ителмәвен инде әйтеп тә торасы юк.

Герцог, барлык боерыкларын биреп бетергәннән соң, д'Артаньян янына килде.

— Хәзер инде, егетем, Англия безнең икебезнең кулыбызда. Сезгә хәзер ни кирәк, ни телисез? — дип сорады ул.

— Ятарга урын кирәк. Ихластыр, хәзер миңа иң кирәк нәрсә — шул, — диде д'Артаньян.

Герцог үзенең йокы бүлмәсе яныннан бер бүлмә бирергә кушты. Егетне ул гел үзе яныңдарак тотарга тели, аның алай итүе д'Артаньянга ышанмаудан түгел, бәлки королева турында һаман-һаман сөйләшерлек гәптәш кирәклектән иде.

Бер сәгатьтән соң Лондонда Франция өчен йөк төягән корабларның диңгезгә чыгуын тыю турында әмер игълан ителде. Хәтта почта йөртә торган пакетботка да рөхсәт юк иде. Бөтенесенең дә фикеренчә, бу хәл ике дәүләт арасында сугыш игълан ителүне аңлата иде.

Өченче көндә иртәнге сәгать унбергә асылташлар әзер

булды. Бу ташлар шул хәтле дә оста итеп охшатып ясалган иде — герцог хәтта үзе дә яңаларын искеләреннән аера алмады, мондый эштәге иң тәҗрибәле кешеләр дә аның хәлендә калырлар иде.

Герцог шул мәлдә үк д'Артаньянны чакыртып китерде.

— Сез алырга килгән асылташлар менә. Шаһит булыгыз: кешенең кулыннан-сәләтеннән килердәйнең бөтенесен эшләтергә тырыштым мин,— диде герцог.

— Борчылмагыз, милорд, күргәннәремнең барысын да сөйләп бирермен. Тик, галиҗәнап, асылташларны тартмасыз бирәсез бит.

— Тартма сезгә юлда комачаулык кына итәр. Аннан ары — миңа бары шул тартма гына кала бит, шуңа күрә минем өчен бик кадерле нәрсә ул. Үзенә алып калды дип әйтерсез.

— Кушканыгызны сүзмә-сүз тапшырырмын, милорд.

— Ә хәзер,— диде герцог, туп-туры егеткә карап,— мин сезгә бурычымны кайчан кайтарырмын соң?

Д'Артаньян чәч төпләренә хәтле кызарынып китте. Ул герцогның егеткә бирәр бүләк бирергә җай эзләвен аңлап алды, минем каным һәм иптәшләрем каны өчен Англия алтыны белән түләмәкче булалар дигән уй күңелендә тирән бер җирәнү тойгысы уятты.

— Ачыктан-ачык сөйләшик, милорд, аңлашылмаучылык булмасын өчен барысын да үлчәп карыйк,— диде моңа каршы д'Артаньян.— Мин Франциянең короле белән королевасына хезмәт итәм, Дезэссар әфәнденең гвардиячеләр ротасы солдатымын, ул да, кайнагасы де Тревиль әфәнде кебек үк, король белән королевага бик тугрылыклы. Ул гына да түгел: сез галиҗәнап, королеваны яраткан кебек, минем дә яраткан бер ханым булмаса, ихтимал, мин бу эшләрне эшләп тә йөрмәс идем.

— Алай икән,— дип куйды герцог көлемсерәп.— Мин ул ханымны беләм шикелле. Ул...

— Милорд, мин аның исемен әйтмәдем бит әле! — дип, гвардияче егет ашыгып аны сүзеннән бүлдерде.

— Дөрес,— диде герцог.— Димәк, сезнең бу фидакарьлегегез өчен мин шул ханымга рәхмәтле булырга тиешмен.

— Нәкъ шулай, галиҗәнап. Чөнки менә хәзер, ике арада сугыш башланырга торганда, мин, ихластан әйтим, сез галиҗәнапны фәкать инглиз кешесе, димәк, дошманым дип кенә күрәм. Мин аның белән Виндзор паркында яисә Лувр коридорларында түгел, бәлки сугыш кырында очрашыр идем. Әмма бу хәл үземә тапшырылган йомышны җиренә җиткереп үтәргә, кирәк икән, аны үтәү өчен җанымны бирергә дә комачауламый. Ләкин кабатлап әйтәм: икенче очрашуыбызда сез галиҗәнапка эшләгән эшләрем өчен, беренче очрашуыбыздагы кебек үк, бик аз бурычлысыз сез миңа.

— Без: «Шотланд кешесе кебек горур» дип әйтәбез,— диде герцог әкренрәк тавыш белән.

— Ә без: «Гасконь кешесе кебек горур» дип әйтәбез. Гасконьлылар алар — француз шотландлылары,— дип җавап кайтарды д'Артаньян.

Егет герцогка баш иде дә китәргә җыена башлады.

— Ничек алай? Китәргә дә җыенасызмыни инде? Нинди юл белән кайтып китмәкче буласыз? Англиядән ничек чыгарга уйлыйсыз?

— Әйе шул, дөрес...

— Ходай орсын мине! Бу французлар беркайчан да аптырап калмыйлар!

— Мин Англиянең бер атау икәнен, ә сез шул атауның хуҗасы икәнлеген онытып җибәргәнмен.

— Хәзер портка барыгыз да «Зунд» бригын сорагыз, менә бу хатны капитанына бирегез. Ул сезне балыкчы көймәләре генә туктый торган бер кечкенә француз гаванена илтеп төшерер.

— Ул гаваньның исеме ничек?

— Сен-Валери. Ашыкмагыз. Анда килеп төшкәч, начар гына бер трактирга керерсез. Аның исеме дә, вывескасы да юк, моряклар җыелып ята торган чын притон. Ялгышуыгыз мөмкин түгел, чөнки андый трактир бер генә анда.

— Шуннан?

— Шуннан соң трактир хуҗасын эзләп табарсыз да аңа: «Forward» дип әйтерсез.

— Мәгънәсе...

— «Алга» дигән сүз. Пароль ул. Шуннан соң трактир хуҗасы сезнең карамакка иярләгән ат биреп, кайсы юлдан китәргә икәнлеген күрсәтер. Юлыгызда сезне алмашка дүрт ат көтеп торыр. Теләсәгез, һәр туктаган төшегездә үзегезнең Париждагы адресыгызны калдыра аласыз, шуннан инде әлеге дүрт атны артыгыздан җибәрерләр, ул атларның икесе сезгә таныш инде, белгеч буларак сез аларныңниндилеген күрдегез шикелле — без икәү Виндзордан атланып кайткан атлар алар. Калганнары да боларыннан ким түгел, миңа ышаныгыз. Ул дүрт ат поход өчен хәзерләп куелган. Бик горур егет булсагыз да, берсен үзегезгә алырсыз, дусларыгыздан да берәр ат алуларын үтенерсез дип уйлыйм. Хәер, алар безгә каршы сугышта бик кирәк булырлар әле. Максатка ярашлы булса, бөтенесе дә яхшы, диләр бит сездә.

— Яхшы, милорд, мин риза. Ходай кушса, бүләгегездән файдалана белербез,— диде д'Артаньян.

— Хәзер инде кулыгызны бирегез, егетем. Сезнең белән озакламый сугыш кырында очрашуыбыз да ихтимал. Ә хәзергә, уемча, сезнең белән яхшы дуслар булып аерылышабыздыр бит?

— Шулай, милорд, тик озакламый дошманнар булу өмете белән аерылышабыз.

— Борчылмагыз, анысы миннән вәгъдә.

— Сүзегезгә ышанам, милорд.

Д'Артаньян баш иеп герцог белән саубуллашты да кызу-кызу атлап портка китте.

Лондон Манарасы каршында әйтелгән бригны эзләп табып, хатны капитанга бирде, капитан аңа порт башлыгыннан имза салдырды да шундук җилкәннәрне күтәрде.

Гаваньда иллеләп кораб, кузгалып китәргә рөхсәт көтеп, әзер булып торалар иде.

«Зунд» бригы аларның берсе яныннан тия язып узды, шул чагында д'Артаньянның күзенә теге вакытта Мёнгта очраган, ят дворян «миледи» дип атаган һәм егетнең үзенә бик чибәр булып күренгән ханым чалынып киткән кебек булды. Әмма каты агым белән арттан искән җил бригны бик тиз йөздереп алып китте һәм якорьда торган кораблар ул арада күздән дә югалды.

Икенче көнне инде иртән, сәгать тугызлар тирәсендә, Сен-Валери гаванена җитеп, якорь ташладылар.

Д'Артаньян бригтан төшү белән үк әйтелгән трактирга китте — эченнән ишетелгән шау-шудан таныды аны. Трактирга җыелган халык Англия белән Франция арасында башланачак сугышны якын арада булачак котылгысыз бер нәрсә итеп сөйли, матрослар шау-гөр килеп кәеф ачалар иде.

Д'Артаньян, халык арасыннан узып, трактир хуҗасы янына килде дә «Forward» сүзен әйтте. Трактирчы, аңа шундук үзе артыннан барырга ымлап, ишегалдына чыкты, егетне абзарга, иярләнгән ат янына алып керде һәм, тагын берәр нәрсә кирәкмиме? — дип сорады.

— Миңа кайсы юл белән китәсемне белергә кирәк,— диде д'Артаньян.

— Иң элек моннан Бланжига барыгыз, аннары Бланжидан Нефшательгә юл тотыгыз. Нефшательдә «Алтын урак» трактирына кереп хуҗасына парольне әйтерсез. Мондагы кебек анда да сезнең өчен иярләгән ат булыр.

— Мин сезгә күпме тиешлемен? — дип сорады д'Артаньян.

— Барысы өчен дә түләнгән, бик мул түләнгән. Юлыгызда булыгыз, ходай сезне ярдәменнән ташламасын,— диде хуҗа.

— Амин! — диде дә егет, атын кушаяклатып чаптырып китте.

Бер дүрт сәгатьтән соң инде ул Нефшательгә килеп җитте. Әйтелгән күрсәтмәләрне җиренә житкереп үтәде. Сен-Валеридагы кебек, Нефшательдә дә аны иярләгән ат көтеп тора иде. Ул әүвәлге иярдәге пистолетларны яңасына алып салмакчы иде дә — яңасында да шундый ук пистолетлар бар булып чыкты.

— Сезнең Париждагы адресыгыз?

— Гвардиячеләр йорты, Дезэссар ротасы.

— Яхшы,— диде хуҗа.

— Кайсы юлдан китәсе миңа?

— Руан юлыннан. Тик сез каланы сулдан урап узарсыз. Экуи дигән кечкенә генә бер авыл янында туктарсыз. Анда «Франция калканы» дигән нибары бер генә трактир бар. Тышкы кыяфәтенә исегез китмәсен. Абзарында минем шикелле ук бер ат булыр.

— Пароль шул укмы?

— Шул ук.

— Сау булыгыз, хуҗа!

— Сау булыгыз, гвардияче әфәнде! Берәр нәрсә кирәкмиме сезгә?

Д'Артаньян «кирәкми» дип баш чайкады да атын җан-фәрманга чаптырып китеп барды.

Экуида да шул ук хәл кабатланды: ачык чырайлы трактир хуҗасы, ял итеп торган яхшы ат. Д'Артаньян элек туктаган төшендәге шикелле, адресын калдырды да шундый ук тизлек белән Понтуазга чапты. Понтуазда соңгы тапкыр ат алмаштыргач, сәгать тугызда, атын кушаяклатып, де Тревиль әфәнде йортының ишегалдына килеп керде.

Унике сәгать эчендә алтмыш мильдән артык юл узды ул.

Де Тревиль әфәнде аны әле бүген иртә белән генә саубуллашкан кеше кебек каршы алды. Гадәттәгедән катырак итеп егетнең кулын гына кысты да Дезэссар әфәндене ротасы Луврда сакта торуын һәм гвардияче егетнең шунда үз постына бара алуын әйтте.

## *XXII*

## *МЕРЛЕЗОН БАЛЕТЫ*

Иртәгәсе көнне бөтен Парижның сөйләгәне король белән королева хөрмәтенә шәһәр башлыклары ясаячак бал турында гына иде. Бу балда король белән королева корольнең иң яраткан балеты Мерлезон балетын биячәкләр икән.

Чыннан да, бу тантаналы кичәгә кадәр бер атна алдан ук инде ратушада зур хәзерлеккә керештеләр. Чакырылган дамаларны урнаштыру өчен шәһәрнең балта остасы күтәрмәләр ясап куйды; шәһәр бакалеячесе залны ул заманда адәм ышанмаслык бер зиннәт дип саналган ак балавыздан ясалган ике йөз шәм белән бизәде; ниһаять, унике скрипкачы чакыртып китерделәр, өстәвенә, аларга уйнаган өчен гадәттәгедән бермәбер артык түләргә булганнар, чөнки, отчетта әйтелгәнчә, алар төн буе уйнарга тиешләр икән.

Иртәнге сәгать унда король гвардиясе лейтенанты де Ла Кост әфәнде, ике полиция офицеры һәм берничә укчы белән, шәһәр секретаре Клемонга килеп, аннардан ратушаның капка, бүлмә һәм ярдәмче биналарының барлык ачкычларын сорады. Ачкычларны ана шундук бирделәр; һәр ачкычка, башкалары

белән саташтырмас өчен, ярлык тагылган иде. Шулай итеп, әлеге минуттан башлап де Ла Кост әфәнде өстенә ратушага керә торган барлык капка һәм аллеяларны саклау бурычы йөкләнде.

Сәгать унбердә, илле укчы белән, гвардия капитаны Дюалье килде. Укчыларны шундук ратуша эченә таратып, һәркайсын үзенә тиешле ишек янына бастырып куйдылар.

Сәгать өчтә ике гвардия ротасы килде — берсе француз ротасы, икенчесе швейцар ротасы иде. Франция гвардиячеләренең ротасы яртылаш Дюалье әфәнде солдатларыннан, яртылаш Дезэссар әфәнде солдатларыннан тора иде.

Кичке сәгать алтыда инде балга чакырылган кунаклар килә башлады. Кунакларның кергән берен олы залда алар өчен махсус әзерләп куелган күтәрмәләргә урнаштыра тордылар.

Сәгать тугызда коннетабль хатыны килде. Королевадан кала тантанада ул иң олуг дәрәҗәле ханым булганлыктан, галиҗәнап шәһәр башлыклары аны каршы алып, королева ложасы каршындагы ложага урнаштырдылар.

Сәгать унда изге Иоанн чиркәве ягындагы кечкенә бүлмәдә, сакка дүрт укчы куелган көмеш савыт-саба буфеты янында, король өчен җинелчә генә закуска әзерләделәр.

Төн уртасы җиткәч, каты-каты кычкырган авазлар, шаугөр килеп алкышлаган-хуплаган тавышлар ишетелде — аллыгөлле фонарьлар белән яктыртылган урамнар буйлап Луврдан ратушага король килә иде.

Шул чагында постау мантия кигән шәһәр башлыклары, кулларына факеллар тоткан алты сержант артыннан, баскычка корольне каршы алырга чыктылар; шунда сәүдә сословиесе башлыгы тәбрик сүзе әйтте; король үзенең сонга калыбрак килүе өчен гафу үтенде, кичегүен кардинал хәзрәтләренә сылтап, сәгать унбергә чаклы дәүләт эшләре хакында сөйләшеп утырдык, диде.

Король парад киемнәрен кигән иде; аны корольнең энесе галиҗәнап герцог Орлеанлы, граф де Суассон, олуг приор, герцог де Лонгевиль, герцог д'Эльбеф, граф д'Аркур, граф де Ла Рош-Гюйон, де Лианкур әфәнде, де Барада әфәнде, граф де Крамайль һәм кавалер де Сувре озата килгәннәр иде.

Корольнең чырае моңсу һәм борчулы икәнлеген бөтенесе сизделәр.

Бер бүлмә махсус король өчен, икенчесе аның энесе герцог Орлеанлы өчен хәзерләп куелган иде. Ул ике бүлмәнең һәркайсында маскарад костюмы бар. Королева белән коннетабль хатыны өчен дә шундый костюмнар хәзерләп куелган иде. Король белән королеваның яраннарыннан булган кавалерлар һәм дамалар, икешәр-икешәр кеше, махсус әзерләнгән бүлмәләрдә киенергә тиешләр иде.

Король үз бүлмәсенә керер алдыннан, кардинал килеп җитү белән миңа хәбәр итәрсез, дип боерык бирде.

Король килеп ярты сәгать үткәннән соң, янадан алкышлар ишетелде,— монысы королева килгәнлеген белгертә иде. Шәһәр башлыклары бу юлы да нәкъ баягыча эшләделәр: сержантлар артыннан атлап, олуг кунак ханымны каршы алырга ашыктылар.

Королева залга килеп керде. Аның да, корольнеке шикелле, чырае күңелсез икәнлеген, бигрәк тә кыяфәте бик йончылган булуын бөтенесе дә сизделәр.

Ул залга килеп кергән чакта кечкенә ложаның монарчы корулы торган пәрдәсе бераз ачыла төште һәм шул ярыкта испан гранды булып киенгән кардиналның агарынган йөзе күренде. Күзләре королеваның күзләренә текәлде, һәм иреннәрендә мәкерле бер елмаю чагылып китте: королева асылташларын такмаган иде.

Королева шәһәр башлыкларының тәбрикләрен кабул итеп һәм дамаларның сәламнәренә каршы сәлам кайтарып бернникадәр вакыт басып торды.

Шул вакыт залның бер ишегеннән король белән кардинал килеп керделәр. Кардинал әкрен генә корольгә нәрсәдер әйтә; корольнең чырае ап-ак иде.

Король, маскасыз, камзул тасмаларын аннан-моннан гына бәйләгән килеш, халык арасыннан узды да королева янына килде.

— Ханым,— диде ул дулкынланудан үзгәргән ят бер тавыш белән,— сорарга рөхсәт итегез: асылташларыгызны нигә такмадыгыз? Минем ул асылташларны түшегездә күрәсем килгәнне белдегез ич.

Королева як-ягына каранды, артта мәкерле генә елмаеп торган кардиналны күрде.

— Галиҗәнап,— диде королева дулкынланып,— бу кадәр халык арасында асылташларга бер-бер хәл булмагае дип курыктым.

— Һәм алай итеп бик ялгыш эшләгәнсез. Мин бит аны сезгә тагып йөрер өчен бүләк иттем. Кабатлап әйтәм, ханым, сез ялгышлык эшләгәнсез.

Корольнең ярсудан хәтта тавышы да калтырана башлаган иде; ни булганын аңламыйча, бөтен кеше бу хәлгә гаҗәпләнеп колак салып карап тора башлады.

— Падишаһым, асылташлар Луврда, кеше җибәреп китертермен дә сез король хәзрәтләренең теләге үтәлер,— диде королева.

— Китертегез, ханым, тизрәк китертегез: тагын бер сәгатьтән балет башлана бит.

Королева күндәмлеген белгертеп баш иде дә үзен аерым бүлмәгә озатып куярга тиешле дамалар артыннан иярде.

Король дә үз бүлмәсенә китте.

Бермәлгә залда шомлы һәм аптырашлы бер тынлык урнашты.

Король белән королева арасында ниндидер аңлашылмаучылык булганлыгы сизелеп тора иде, ләкин алар үзара әкрен генә сөйләштеләр, сүзләрен берәү дә ишетмәде, чөнки аларга хөрмәт йөзеннән бөтен кеше берничә адым читкәрәк тайпылган иде. Скрипкачылар кызып-кызып музыка уйный, тик аларны беркем дә тыңламый иде.

Беренче булып залга король килеп керде; өстенә бик нәфис, зиннәтле аучы костюмы киеп алган иде ул. Энесе герцог Орлеанлы белән башка олуг затлар да король шикелле киенгәннәр. Бу костюм корольгә ифрат та килешеп тора, шуны киеменнән ул чыннан да үз дәүләтендә иң күркәм дворяндыр кебек тоела иде.

Кардинал, король янына килеп, аңа ниндидер тартма сузды.

Король, тартманы ачып карагач, ике асылташ күрде.

— Бу ни нәрсә? — дип сорады ул кардиналдан.

— Искитәрлек нәрсә түгел,— диде кардинал,— әгәр королева асылташларын таккан булса,— мин аның тагуына шикләнәм,— сез ул асылташларны, падишаһым, санап карагыз әле. Әгәр ун гына калган булса, олуг ханымнан: «Менә бу икесен кем урлаган булуы ихтимал?» дип сорагыз.

Король төшенеп җитмәгән бер төс белән кардиналга карады, ләкин аңардан сорарга өлгермәде: бөтен зал халыкның сокланып кычкырган авазлары белән тулды. Король үз дәүләтенең иң күркәм дворяныдыр кебек тоелган булса, королева, һичшиксез, Франциянең иң гүзәл бер ханымы иде.

Чыннан да, сунарчы костюмы королевага искиткеч килешеп тора иде: аның башында зәңгәр каурыйлы фетр эшләпә, өстендә асылташ каптырмалы көлсурак энҗе төсендәге бәрхет лиф, тоташтан көмеш ука белән чигелгән зәңгәр атлас юбка. Сул кулбашында каурыйлар һәм юбка төсендәге бант белән эләктереп куелган асылташлар елык-елык итеп тора иде.

Король — шатлыгыннан, ә кардинал — ярсуыннан тетрәнә башладылар, ләкин алар әле королевадан шактый ерак, асылташларны санарлык арада түгел иделәр; королева асылташларны тагуын таккан, тик ничәү икән алар — унмы әллә уникеме?

Шул мәлне, балетның башлануын белгертеп, скрипкачылар музыка уйнап җибәрделәр. Король коннетабль хатыны янына килде — ул аның белән биергә тиеш иде, энесе герцог Орлеанлы королева янына барды. Бөтенесе урыннарына басуга, балет башланып та китте.

Король королева каршысында бии иде, шуна күрә ул аның яныннан узган саен күзе белән ашардай булып асылташларга карый, аларны һич саный алмый иде. Кардиналның исә маңгаена салкын тир бәреп чыккан иде.

Балет бер сәгать чамасы дәвам итте; анда уналты тапкыр биюгә чыгу булды.

Балет беткәч, һәр кавалер бөтен залның алкышы астында дамасын урынына илтеп утыртты, әмма король, үзенең зур хокукыннан файдаланып, дамасын шунда калдырды да ашыгып королева янына килде.

— Минем теләгемә бик илтифатлы булганыгыз өчен сезгә, ханым, рәхмәтемне белдерәм, тик сезнең ике асылташыгыз җитеп бетми шикелле, менә мин аларны сезгә кайтарам,— диде ул королевага.

— Ничек ул алай, әфәндем?! — дип, бик гаҗәпләнгән булып кычкырып әйтеп куйды яшь королева.— Сез миңа тагын ике асылташ бүләк итәсезмени? Ул чагында минем ундүрт асылташым була ич!

Король санап карады: чыннан да, уникe асылташның уникесе дә королеваның түшендә иде.

Король кардиналны чакырып алды.

— Я, кардинал җәнаплары, бу ни дигән сүз? — дип кырыс бер тавыш белән сорады король.

— Шулай дигән сүз ул, падишаһым: мин бу ике асылташны олуг ханымга бүләк итмәкче идем, тик үзем тапшырырга җөрьәт итмичә, шушы ысулны кулландым,— дип җавап бирде кардинал.

— Сез кардинал хәзрәтләренә монысы өчен дә бик рәхмәтлемен,— дип җавап кайтарды Анна Австрияле, кардиналның бу тапкырлыгына алданмавын сиздереп көлемсерәп куйды,— бу ике асылташның бәһасе король хәзрәтләре өчен уникесе күпме торган булса, сезнең өчен дә шулкадәргә төшкәндер.

Шуннан соң инде королева король белән кардиналга баш иеп алды да үзенең өс-башын алмаштыра торган бүлмәгә китте.

Бу бүлекнең башында без үзебез тасвир иткән олуг шәхесләргә артык игътибар биреп, д'Артаньяннан беркадәр читләшеп тордык. Анна Австрияленең кардиналны җиңеп чамасыз тантана итүенә сәбәпче булган кеше хәзер, ыгы-зыгы килгән халык арасында, беркем күзенә чалынмыйча, аптырашлы кыяфәттә, бер ишек төбендә, бары тик дүрт кенә кешегә: король белән королевага, кардинал хәзрәтләренә һәм үзенә генә билгеле булган әлеге тамашаны күзәтеп тора иде.

Королева үз бүлмәсенә кереп китте.

Д'Артаньян китәргә кузгалыйм дип кенә торганда, кемдер килеп әкрен генә җилкәсенә кагылганын тойды; борылып карагач, яшь кенә бер хатынны күрде. Хатын аңа ымлап кына үзе артыннан ияргә кушты. Яшь хатын йөзен кара бәрхеттән теккән ярым маска белән каплаган иде, ләкин, шундый саклык чарасы күрүенә дә карамастан (хәер, моны ул егеткә түгел, бәлки башкаларга танытмас өчен эшләгән иде), егет үзенең даими юл күрсәтүчесен — чая һәм тапкыр сүзле Бонасье ханымны шундук танып алды.

Моннан алдагы көнне алар капка сакчысы Жермен янында, д'Артаньян ханымны чакырып чыгаргач, бик азга гына күрешеп алганнар иде. Яшь ханым атчабар егетнең исән-сау йөреп кайту хәбәрен тизрәк королевага җиткерергә ашыкканлыктан, гашыйклар бер-ике авыз гына сүз сөйләшеп калдылар. Шуңа күрә д'Артаньянны ике тойгы — мәхәббәт һәм кызыксыну тойгысы — Бонасье ханым артыннан ияррергә мәҗбүр итте. Барган чакта коридорларда кеше азайган саен д'Артаньян яшь ханымны туктатырга, беләгеннән тотып алып, бер мизгел генә булса да яратып күз салырга теләде, тик чыпчык шикелле җитез Бонасье ханым шундук аның кулыннан ычкынды, егет сүз кушмакчы булгач, яшь ханым, ярамый дигән мәгънә белән, бармагын шундый да сөйкемле-матур итеп авызына куйды. Моның белән ул үзләре өстеннән власть хакимлек итүен, алар шуңа сукыр рәвештә буйсынырга тиешлекләрен һәм ул власть егеткә аз гына да зарланырга юл куймаганлыгын д'Артаньянның исенә төшерде. Ниһаять, бик күп аралыклар, ишекләрдән узгач, Бонасье ханым бер ишекне ачты да егетне дөм-караңгы бер бүлмәгә алып керде. Монда ул егеткә янә, пышылдап кына, сөйләшмәскә кушты. Һәм, кинәт бүлмә эченә якты сирпелдереп, драпировка артына яшерелгән икенче бер ишекне ачты да юкка чыкты.

Д'Артаньян, «мин кайда соң?» дип уйлана-уйлана, беравык хәрәкәтсез басып торды, тик озакламый күрше бүлмәдән саркып кергән ут яктысы, шул яктан тәмле исле җылы һава агылуы, ике-өч хатынның ихтирамлы һәм нәзакәтле итеп сөйләшүләре, берничә тапкыр «олуг ханым» дип эндәшүләре — болар барысы тәгаен егетнең королева бүлмәсе белән янәшә кабинетка килеп эләккәнлеген белгертте.

Егет караңгыга посып көтеп тора башлады.

Королева бик кәефле, шат күренә, аны һәрвакыт борчулы, кайгылы итеп күрергә гадәтләнгән дамаларга аның бу халәте бик гаҗәп тоела иде, ахры. Королева үзенең шат-кәефле булуын бәйрәмнең бик матур, күңелле булуыннан, балетның бик ошавыннан дип аңлатты. Королева еласа да, көлсә дә, аңа каршы әйтергә ярамаганлыктан, дамалар Париж каласы башлыкларының кунакчыллыгын күккә чөеп мактадылар.

Д'Артаньян королеваны күреп белми иде, шулай да бераздан аның тавышын башкаларныкыннан аера башлады — башта беркадәр чит милләт акцентыннан, аннары олуг шәхесләрнең һәр сүзендә сизелә торган боеру тоныннан таныды.

Ул королеваның бу ачык ишеккә әле якынаюын, әле ерагая төшүен ишетеп торды, ике-өч тапкыр хәтта яктыны каплаган күләгәсен дә күрде.

Һәм шунда кинәт сокландыргыч бер нәфис ак кул драпировка аша бу якка сузылды. Д'Артаньян моның үзенә бүләк икәнен төшенеп алды: идәнгә тезләнеп, бу кулны тотты да ихтирам белән иренен тидерде. Шуннан соң әлеге кул, егетнең учына

нәрсәдер салып, юкка чыкты. Д'Артаньянның учындагы әйбер йөзек иде.

Ишек шул минутта ук ябылды да д'Артаньян дөм-караңгыда калды.

Егет, йөзекне бармагына киеп, тагын көтә башлады; моның белән генә эш бетмәгәнлеген аңлый иде ул. Тугрылык бүләгеннән соң мәхәббәт бүләге дә килергә тиеш бит.

Өстәвенә, балет инде беткән булса да, кичәсе әле башланды гына; аш мәҗлесе сәгать өчкә билгеләнгән, изге Иоанн манарасындагы сәгать исә әлерәк кенә өченче өч чирекне суккан иде.

Чыннан да, күрше бүлмәдәге тавышлар әкренләп тына, сраклаша башлады, шуннан соң д'Артаньян кергән бүлмәнең ишеге яңадан ачылды да бүлмәгә Бонасье ханым йөгереп килеп керде.

— Сезме бу?! Ай-һай көттердегез! — дип кычкыра төшеп эндәште д'Артаньян.

— Тавышыгызны чыгармагыз! — диде яшь ханым, кулы белән аның авызын каплап.— Килгән юлыгыз белән тып-тын гына китегез.

— Мин сезне кайда һәм кайчан күрермен соң? — дип кычкыра биреп сорады д'Артаньян.

— Өегездә хат булыр, шуннан укып белерсез. Барыгыз инде, китегез!

Шулай дип, ханым коридор ягындагы ишекне ачты да д'Артаньянны бүлмәдән чыгарып җибәрде.

Егет, сүз тыңлаган бала шикелле, карышмады, буйсынды, каршы бер сүз дә әйтмәде. Монысы инде аның чыннан да гашыйк булганлыгын күрсәтеп тора иде.

## XXIII

## КҮРЕШҮ

Д'Артаньян йөгерә-чаба өенә кайтып китте, вакыт инде иртәнге сәгать өчтән ашкан иде, егеткә Парижның иң куркыныч кварталларын узарга туры килсә дә, ул берниндн күңелсез хәлгә очрамады. Һәркемгә мәгълүм: исерекләр белән гашыйкларның сакчы фәрештәләре була, имеш.

Йортның тышкы ишеге ярым ачык иде; д'Артаньян баскычтан квартирына менде дә үзе һәм хезмәтчесе генә белгән шартлы билге белән әкрен генә ишекне шакыды. Планше килеп ишекне ачты. Д'Артаньян, мине өйдә көтәрсең дип, моннан ике сәгать элек аны ратушадан кайтарып җибәргән иде.

— Миңа хат китерүче булмадымы? — дип тиз генә сорады д'Артаньян.

— Юк, әфәндем, китерүче булмады, ә менә үз аягы белән килеп кергән бер хат бар,— диде Планше.

— Ни дигән сүз ул, ахмак?

— Шулай дигән сүз ул: мин өйгә кайтып керсәм, сезнең йокы бүлмәгездә өстәлдә бер хат ята иде, югыйсә, квартир ачкычы минем кесәмдә иде.

— Кайда ул хат?

— Мин аны, әфәндем, шунда урынында калдырдым. Менә хикмәт түгел диген: шул рәвешчә өйгә хат килеп керсен әле! Ичмасам, тәрәзә ачык булса икән әле, һич югы ярык калган булса икән — ул чагында сүз әйтмәс идең. Юк бит, алай түгел, тәрәзә нығытып ябылган. Берүк сак булыгыз, әфәндем, тәгаен, адәм эше түгел бу, шайтан эше.

Д'Артаньян, аны тыңлап тормастан, бүлмәгә кереп китте дә хатны алып ачты; бу хатны Бонасье ханым язган, менә мондый юллар бар иде анда:

«Сезгә үз исеменнән һәм шулай ук икенче бер кеше исеменнән бик зур рәхмәт әйтергә телиләр. Бүген кичке сәгать унга Сен-Клуга, д'Эстре әфәнде йорты янындагы павильон каршына килегез.

*К. Б.»*

Д'Артаньян бу хатны укыган чагында гашыйкларның күңеленә газап та, рәхәтлек тә китерә торган татлы бер калтыранудан йөрәге әле киңәеп, әле кысылып-кысылып куюын тойды.

Бу аның сөйгәненнән беренче тапкыр хат алуы, беренче тапкыр күрешергә сүз куешуы иде. Аның һушларга китәрлек бәхет-шатлык белән тулып ашкан йөрәге фани дөньядагы мәхәббәт дигән оҗмахның бусагасы төбендә туктап калырга да әзер иде.

Планше, хуҗасының бер кызарынуын, бер агарынуын күреп:

— Я, нәрсә, әфәндем? Я, нәрсә?! Дөрес әйткәнменме, берәр төрле әшәке нәрсәме? — дип сорады.

— Ялгышасың, Планше,— диде д'Артаньян,— ялгышканың өчен менә сиңа бер экю, минем исәнлеккә шәраб эчәрсең.

— Экю өчен рәхмәт, әфәндем, кушканыгызны җиренә җиткереп үтәрмен, тик шунысы да хак: бикле йортка бу рәвешле килеп керә торган хатлар...

— Күктән явалар, дустым, күктән явалар.

— Димәк, әфәндем, сез канәгать? — дип сорады Планше.

— Планше дустым, бу дөньяда хәзер мин иң бәхетле бер бәндәмен.

— Ә мин, сезнең ул бәхетегездән файдаланып, йокларга да ята аламмы?

— Әйе, әйе, ят та йокла.

— Берүк ходайның рәхмәте иңсен үзегезгә, әфәндем, әмма шунысы да хак: әлеге хат...

Планше, д'Артаньянның юмартлыгы гына шигемне бетерә алмады шул дигәндәй, башын чайкый-чайкый чыгып китте.

Егет, ялгызы калгач, хатны яңадан укыды, тагын бер тапкыр укыды, аннары сөекле гүзәленең кулы белән язылган юлларны бер егерме тапкыр үбеп-үбеп алды. Ахырында ятып йокыга китте, матур-матур төшләр күрә башлады.

Иртәнге сәгать җидедә ул, йокысыннан торып, Планшены чакырды. Икенче тапкыр эндәшүгә, хезмәтчесе ишекне ачып карады, Планшеның кыяфәтендә кичәге шик-борчуларының галәмәте бетеп җитмәгән иде әле.

— Планше, мин китәм, бәлки, көн буе йөрермен. Шулай итеп, син кичке җидегә хәтле азатсың, ләкин сәгать җидегә ике ат белән әзер булып тор,— диде д'Артаньян.

— Алай икән! Без тагын тиреләребезне тишкәләтергә барабыздыр инде,— дип куйды Планше.

— Мушкет белән пистолетларны алырсың.

— Әйттем бит шулайдыр әле дип! — диде Планше, тавышын күтәрә төшеп.— Җүнле хат түгелдер дип уйлаган идем шул аны!

— Юкка хафаланма, аңгыра баш, болай йөреп кенә кайтабыз.

— Әйе, шулайдыр, теге күңелле сәфәрдә өскә пуля яңгыры явып, җирдән капкыннар калкып чыккандагы кебектер.

— Хәер, Планше әфәнде, курка торган булсагыз, сездән башка гына китәрмен,— диде д'Артаньян.— Дер калтырап торган юлдаш ияртеп йөргәнче үзем генә китү хәерлерәк булыр.

— Сез мине рәнҗетәсез, әфәндем,— диде Планше бу сүзгә каршы.— Минем ниндилегемне күргәнегез булды бит инде.

— Булуын булды да, тик син бөтен батырлыгыңны берьюлы чыгарып бетерден шикелле.

— Җае чыккач күрерсез әле, әфәндем: миндә калган кадәресе дә ярыйсы әле, тик минем ул батырлыгым күпкә җитсен дисәгез, зинһар, артык юмарт тотмагыз аны.

— Ә үзең ничек уйлыйсың соң: бүген кичкә җитәрлек батырлыгың калганмы синең?

— Әлбәттә.

— Алайса, бик шәп! Мин сиңа ышанам.

— Әйтелгән сәгатькә мин әзер булырмын. Тик, әфәндем, минем уемча, гвардиячеләр абзарында сезнең атыгыз бер генә бугай?

— Ихтимал, хәзер бер генәдер, ә менә кичкә дүртәү булыр.

— Әллә без атлар сатып алырга барган идекме?

— Нәкъ шулай,— диде д'Артаньян.

Һәм, саубуллашып, Планшега боерган сыман кул селтәде дә өйдән чыгып китте.

Тыштагы ишек төбендә Бонасье әфәнде басып тора иде. Д'Артаньян мөхтәрәм галантерейчыга сүз кушмыйча гына үтеп китмәкче булган иде дә, Бонасье шундый ягымлы, шундый эчкерсез итеп исәнләште ки, йорт хуҗасының сәламенә каршы сәлам биреп кенә калмыйча, сүз кушарга да туры килде.

Бүген кич Сен-Клуда, д'Эстре әфәнденең павильоны каршында синең белән күрешергә дип сүз куешкан чибәр ханымның иренә ничек инде беркадәр ачык чырай күрсәтмисең ди! Д'Артаньян, булдыра алган кадәр якты йөз күрсәтергә тырышып, Бонасье әфәнде янына килде.

Билгеле инде, иң элек сүз ул бичараның төрмәдә утырып чыгуы турында булды. Бонасье әфәнде, үзенең Мөңгта егеткә очраган ят кеше белән әңгәмәсен д'Артаньян тыңлап торганлыгын белмичә, фатирчысына залим Лафемның кансызлыгы-шәфкатьсезлеге турында сөйләде, аны әледән-әле кардиналның палачы дип атады, егеткә Бастилияне, ишектәге бикләрне, төрмә форточкаларын, рәшәткәләрен һәм җәза коралларын тәфсилләде.

Д'Артаньян аны зур игътибар белән тыңлап торды.

— Әйтегез әле: теге вакытта Бонасье ханымны кем урлаганлыгын белә алдыгызмы сез, юкмы? — дип сорады егет, Бонасье әфәнде сүзен сөйләп бетергәч.— Хәтеремдә: безнең танышып китүебезгә дә шул күңелсез хәл сәбәпче булган иде бит.

— Аһ,— дип авыр сулап куйды Бонасье әфәнде,— әлбәттә, алар миңа анысын әйтмәделәр, хатыным да белмим дип ант итеп әйтте. Ә сез соң,— диде Бонасье әфәнде ихлас бер төс белән,— соңгы көннәрдә кайда югалып йөрдегез? Мин сезне дә, дусларыгызны да күрмәдем. Кичә итекләрегездән Планше чистарткан шулкадәр тузанны Париж урамнарыннан гына җыймагансыздыр дип беләм.

— Хак сөйлисез, хөрмәтле Бонасье әфәнде, без дусларыбыз белән бераз сәяхәт кылып кайттык.

— Ерак бардыгызмы инде?

— Юк, әллә ни ерак түгел, моннан кырык лье чамасы. Атос әфәндене Форжга шифалы суга озатып куйдык, дусларым әле шунда калдылар.

— Ә сез, сез инде, әлбәттә, кире кайттыгыз,— диде Бонасье әфәнде, йөзенә хәйләкәр бер төс чыгарып.— Сезнең ише чибәр егеткә сөяркәләре озак югалып йөрергә рөхсәт итмидер шул, сезне инде Парижда түземсезләнеп көтеп торганнардыр, шулаймы?

— Шулай, хөрмәтле Бонасье әфәнде. Ихластыр, шулай,— диде егет, көлә-көлә.— Сездән берни дә яшереп булмый, күрәсең. Әйе, мине көтеп торганнар, ихластыр, түземсезләнеп көткәннәр.

Бонасьеның чыраена бераз гына караңгы төс инде — д'Артаньян моны сизми дә калды.

— Шулай ашыгуыбыз өчен әҗер тиешлеме инде безгә? — диде галантерейчы бераз гына ятрак тавыш белән. Д'Артаньян, мөхтәрәм әфәнденең элерәк кенә чыраена иңгән караңгы төсне шәйләми калган кебек, бу үзгәрешне дә сизмәде.

— Һай, сезнең юраганыгыз юш килсә иде! — диде д'Артаньян көлә-көлә.

— Боларны әйтүем шуңа: сез бик соңга калып кайтачаксызмы?

— Бу соравыгызның мәгънәсе ни, хөрмәтле хуҗам? — диде д'Артаньян.— Минем кайтканны көтеп торырга җыенмыйсыздыр бит?

— Юк, мин төрмәгә кереп чыкканнан бирле һәм дә акчамны урлатканнан бирле ишек ачылган саен, бигрәк тә төнлә ачылганда, курка торган булып калдым. Нишлисең бит, солдат кеше түгел шул мин.

— Соң, алайса, мин төнге сәгать бердә, икедә яки өчтә кайтсам да курыкмагыз. Хәтта бөтенләй кайтмый калсам да исегез китмәсен.

Бу юлы инде Бонасьеның чырае көл төсле агарынып китте, монысын д'Артаньян да сизми калмады һәм:

— Ни булды сезгә? — дип сорады.

— Зарар юк, зарар юк,— диде Бонасье.— Әнә шул бәлаләрдән соң мин авыру булып калдым, кинәт кенә өянәк тота башлый үземне, менә әле генә бөтен тәнем чымырдап китте. Сез миңа әһәмият итмәгез, сезнең бит башка шөгылегез дә бар — бәхетегезне татыйсыгыз бар.

— Ул чагында инде мине зур эш көтә, чөнки мин чыннан да бик бәхетлемен.

— Хәзергә көтми әле, бераз сабыр итегез — сез аны кич булгач дидегез бит.

— Нигә, ходайның рәхмәте белән ул кич килми калмас! Бәлки, аны сез дә минем кебек түземсезләнеп көтәсездер. Бәлки, бүген кич Бонасье ханым иренең куышына кайтып китәр.

— Бонасье ханым бүген кич кайта алмый шул,— диде ир кеше җитди бер төс белән.— Эш вазифасы Луврда калырга мәҗбүр итә.

— Ул чагында хәлегез әйбәт түгел икән, кадерле хуҗам, хәлегез әйбәт түгел. Үзем бәхетле чагында мин башкаларның да бәхетле булуын телим, тик гел алай булып бетми бугай шул.

Егет, мәгънәсен үзем генә аңлыйм дигәндәй, тапкыр сүзеннән шаркылдап көлә-көлә китеп барды.

— Кәеф-сафалар чигегез! — дип калды Бонасье кабердән чыккан сыман бер тавыш белән.

Тик д'Артаньян шактый ерак китеп өлгергән иде инде, бу сүзне ишетмәде, хәер, ишетсә дә, кәефе бик хуш булганлыктан, егет мондый сүзгә әллә ни әһәмият бирмәгән дә булыр иде.

Ул де Тревиль әфәнде йортына таба юл тотты; хәтерләвебезчә, кичә аның визиты бик кыска булган һәм ул рәтләп берни дә сөйли алмаган иде.

Д'Артаньян де Тревиль әфәндене бик кәефле-шат чагына туры килде. Король белән королева балда аңа гаҗәеп дәрәҗә-

дә ачык чырай күрсәткәннәр. Аның каруы кардиналның чырае бик караңгы булган.

Төнге сәгать берләрдә кардинал кәефем юк дип балдан кайтып киткән. Король белән королевага килгәндә исә, алар Луврга иртәрге сәгать алтыда гына кайтканнар.

— Ә хәзер инде,— диде де Тревиль әфәнде, тавышын әкренәйтә төшеп, берәр чит кеше юкмы дигәндәй, бүлмәнең барлык почмакларын тикшереп-карап чыкты,— хәзер инде, егетем, сезнең хакта сөйләшик, чөнки сезнең исән-сау йөреп кайтуыгызның корольнең шатлыгына, королеваның тантана итүенә һәм кардинал хәзрәтләренең хурлыкка калуына да беркадәр бәйләнеше бар. Хәзер инде сезгә бик сак булырга кирәк.

— Король белән королеваның миңа карашлары яхшы булганда нәрсәдән куркыйм икән мин? — диде д'Артаньян.

— Бик күп нәрсәдән куркырга кирәк, ихластыр. Кардинал ул андый усал шаяруны онытып, үч алмый кала торган кеше түгел. Ә ул усал шаяручы кеше исә әлеге таныш Гасконь егете түгел микән дип шикләнәм мин.

— Ул хәлләрне кардинал да сезнең кебек үк яхшы беләме, минем Лондонга барып кайтуымнан да хәбәрдар дип уйлыйсызмы?

— Ах, шайтан! Сез Лондонга ук барып кайттыгызмыни? Бармагыгызда ялтыраган асылташны да Лондоннан алып кайттыгызмы әллә? Сак булыгыз, д'Артаньян дускай, дошманның бүләк бирүе хәерлегә түгел ул. Бу хакта бер латин шигыре дә бар... Туктагыз әле...

— Әйе, әйе, бар шул,— диде д'Артаньян, үзе исә латин теленең иҗеген дә өйрәнә алмаган һәм наданлыгы белән укытучысының гайрәтен чигереп бетергән иде,— әйе, әйе, ниндидер бер шигырь булырга тиеш шул...

— Әлбәттә, бар ул шигырь,— диде де Тревиль әфәнде,— әдәбиятка беркадәр һәвәслеге бар иде аның,— әле күптән түгел генә де Бенсерад әфәнде укыган иде аны миңа... Сабыр итегез... Әһә, искә төште!

Timeo Danaos et dona ferentes *.

Мәгънәсе «үзеңә бүләк бирүче дошманнан курык» дигән сүз.

— Әфәндем, бу асылташны миңа дошманым бирмәде, моны миңа королева бүләк итте,— диде д'Артаньян.

— Королева?! Оho! — диде де Тревиль.— Әйе, чыннан да королева бүләге шул бу. Бу йөзекнең бәһасе мең пистольдән дә ким түгелдер. Королева моны сезгә кем аркылы бирдерде инде?

— Үзе бирде.

— Кайда?

— Өс-башын алмаштырган бүлмә белән янәшә кабинетта.

---

* Хәтта бүләк китерүче данайлылардан да куркам (*латинча*).

— Ничек итеп?

— Кулын үптерергә дип сузгач.

Де Тревиль, исе киткән бер кыяфәт белән д'Артаньянга карап, кычкырып әйтә салды:

— Сез королеваның кулын үптегезмени?!

— Әйе, олуг ханым миңа шундый хөрмәт күрсәтте.

— Шунда шаһитлар да бар идеме? Һай, саксызның да саксызы!

— Юк, әфәндем, борчылмагыз, ул эшне беркем күрмәде,— дип җавап бирде д'Артаньян.

Һәм шуннан соң де Тревиль әфәндегә хәлнең ничек булганлыгын сөйләп бирде.

— Һай, хатыннар, хатыннар! — дип кычкырып әйтә куйды карт солдат.— Романтик хыялларыннан ук таныйм мин аларны. Серле булып күренгән бөтен нәрсәгә мөкиббән китәләр... Димәк, сез аның кулын гына күреп калдыгыз. Королеваны күрсәгез, сез аны танымыйсыз, ул сезне күрсә — сезнең кем икәнегезне белми.

— Шулай инде, ә менә бу асылташтан...— диде егет, каршы килеп.

— Карагыз әле, сезгә бер киңәш, яхшы киңәш, дусларча киңәш биримме? — диде де Тревиль әфәнде.

— Миңа бик зур хөрмәт күрсәтүегез булыр иде ул, әфәндем,— дип җавап бирде д'Артаньян.

— Алайса, болай итегез: беренче очраган алтын остасына барыгыз да, ни хак сораса, шул бәһагә бу асылташны сатыгыз. Никадәр саран булса да, моның өчен сезгә сигез йөз пистольдән дә ким тими калмас. Пистольнең исеме юк аның, егетем, ә менә йөзекнең исеме бар, бик хәтәр исеме бар, шул исем йөзекне бармагында йөрткән кешене харап итүе ихтимал.

— Бу йөзекне сатарга дисезмени? Олуг ханым бүләк иткән йөзекне?! Һич юк! — диде д'Артаньян, кычкыра төшеп.

— Ул чагында ташын эчкә әйләндертегез, акылсыз бәндә, чөнки ярлы бер Гасконь дворянының андый асылташны әнисе котыйчыгыннан тапмаганлыгын бөтен кеше белә бит.

— Миңа бер-бер куркыныч булуы ихтимал дип уйлыйсызмыни? — диде д'Артаньян.

— Мин сезгә шуны әйтәм, егетем: фитиленә ут төрткән мина өстенә ятып йоклаган кеше үзен сездән куркынычсызрак хәлдә дип саный ала.

— Шайтан алгыры! — дип куйды д'Артаньян, де Тревильнең ышандыргыч итеп сөйләвенә борчыла башлап.— Шайтан алгыры, нишләргә икән соң инде миңа?

— Һәркайда, һәр җирдә сак-уяу булырга кирәк. Кардиналның хәтере бик яхшы, кулы бик озын. Ихлас әйтәм: ул сезгә бер-бер әшәкелек эшләми калмаячак.

— Нинди әшәкелек?

— Һе! Каян белим мин аны?! Иблистәге бөтен хәйлә-мәкерне җыйган бит ул үзенә! Һич югы, сезне кулга алулары ихтимал.

— Ничек инде?! Корольгә хезмәт итүче солдатны кулга алырга кемнең намусы җитәр икән?

— Шайтаным! Ә Атосны кулга алганда уңайсызланып-тартынып тордылармы? Кыскасы, король сараенда утыз ел хезмәт иткән кешенең сүзенә ышана күрегез, егетем: артык гамьсезваемсыз булмагыз, югыйсә, харап булуыгыз бар. Киресенчә — моны сезгә мин әйтәм — сез һәр җирдә дошманнарыгызны күрергә тиешсез. Әгәр берәрсе сезнең белән талашып китәргә маташа икән — ул кеше ун яшьлек бала булса да, сез аннан тайпылырга тырышыгыз. Күпер аша чыккан чакта такталарны әйбәтләп капшап карагыз, чөнки аның берәр тактасы төшеп китүе ихтимал. Салынып яткан йорт яныннан узганда өскә күтәрелеп карагыз: башыгызга таш килеп төшүе мөмкин. Өегезгә соң кайтсагыз — артыгыздан хезмәтчегез кайтсын, хезмәтчегез кораллы булсын,— әлбәттә, аның көченә ышанган тәкъдирдә. Бөтен кешедән шикләнә торган булыгыз: дустыгыздан да, туганыгыздан да, сөяркәгездән дә... бигрәк тә сөяркәгездән.

Д'Артаньян кызарынып китте. Ихтыярсыздан:

— Сөяркәмнән?..— дип кайтарып сорады.— Ә ни өчен мин бигрәк тә сөяркәмнән шикләнергә тиешмен соң?

— Чөнки сөяркә ул кардиналның иң тиз нәтиҗә бирә торган яраткан чараларыннан берсе: хатын-кыз ул сезне ун пистоль акчага да сатып җибәрә. Дәлиләне хәтерләгез. Изге китапны беләсезме сез?

Д'Артаньян шушы кичтә Бонасье ханым белән күрешергә дип сүз куешканлыкларын исенә төшерде, ләкин героебызны мактап шуны әйтергә тиешбез: де Тревиль әфәнденең гомумән хатын-кыз турындагы начар фикере егетнең чибәр хуҗабикәсенә карата аз гына да шик-шөбһәсен уятмады.

— Карагыз әле, кая юкка чыкты сезнең өч юлдашыгыз? — дип сорады де Тревиль әфәнде.

— Мин үзем дә әле, алар хакында берәр мәгълүмат алмадыгызмы? дип сорамакчы идем.

— Бернинди мәгълүмат юк.

— Мин аларны юлда калдырып киткән идем: Портос Шантильида дуэльдә сугышырга җыенып калды, Арамис Кревкерда кулбашына пуля тиеп калды, ә Атос Амьенда ялган акча белән эш итә дип гаепләнеп калды.

— Алай икән! — дип куйды де Тревиль әфәнде.— Ә үзегез соң ничек ычкындыгыз?

— Могҗиза белән генә, әфәндем, дөресен әйтим, могҗиза белән генә ычкындым: күкрәгемә кылыч белән кададылар, ә үзем граф де Бардны Калега бара торган юл буенда обойга күбәләк ябыштырган шикелле кадаклап калдырдым.

— Шул гына җитмәгән иде инде! Кардиналның тарафдары, Рошфорның кардәше де Вард белән алай кылану!.. Карагыз әле, дустым, минем башка бер фикер килде әле.

— Нинди фикер, әфәндем?

— Мин сезнең урында булсам, бер нәрсә эшләр идем.

— Нинди нәрсә?

— Кардинал хәзрәтләре мине Париждан эзләсә, мин шул арада, беркемгә белгертмичә, шыпырт кына Пикардиягә китәр идем дә өч юлдашымның хәлләрен белешер идем. Чынлап, алар сезнең андый гына илтифатыгызга лаек бит.

— Бик яхшы киңәш бу, әфәндем, иртәгә үк китәмен.

— Иртәгә! Ә нигә бүген үк кич түгел?

— Бүген мин, кичектергесез бер эш аркасында, Париждан чыгып китә алмыйм шул.

— Һай, егетем, егетем! Берәр төрле яшьлек мавыгуыдыр инде? Кабатлап әйтәм, сак булыгыз: хатын-кыз элек тә безне харап итте, киләчәктә дә харап итәчәк. Сүземне тыңлагыз, бүген үк кич китегез.

— Булмый, әфәндем.

— Димәк, сез аңа сүз бирдегез?

— Әйе, әфәндем.

— Ул чагында инде башка эш. Шулай да, әгәр сезне бүген төнлә үтерми калсалар, иртәгә китәм дип миңа вәгъдә бирегез.

— Вәгъдә.

— Сезгә акча кирәкмиме?

— Минем илле пистоль акчам бар әле. Җитәр дип уйлыйм.

— Ә юлдашларыгызның?

— Аларның да акчалары булырга тиеш дип уйлыйм. Париждан чыгып киткән чакта һәркайсыбызның кесәсендә җитмеш бишәр пистоль акчасы бар иде.

— Сезне киткәнче тагын күрә аламмы әле мин?

— Күрә алмассыз дип уйлыйм, әфәндем, яңадан бер-бер хәл килеп чыкмаса.

— Алайса, хәерле юл сезгә.

— Рәхмәт, әфәндем.

Шуннан соң д'Артаньян, де Тревиль әфәндедән мушкетерлар турында аталарча кайгыртуына бик күңеле булып, аның белән саубуллашты да чыгып китте.

Ул берочтан Атос, Портос һәм Арамисларның квартирларын йөреп чыкты. Аларның берсе дә әле өенә кайтмаган. Хезмәтчеләре дә өйдә юк, ни тегеләре, ни болары турында беркемдин хәбәр-хәтер юк иде.

Д'Артаньян егетләр хакында аларның сөяркәләреннән белешкән булыр иде дә, тик ул Портос сөяркәсен дә, Арамисныкын да белми, Атосның исә сөяркәсе бөтенләй юк иде.

Гвардия казармалары янынннан узганда ул абзарга кереп чыкты: дүрт атның өчесе инде килеп җиткән иде. Планше, бу

хәлгә шаккатып, аларны кыргыч белән чистартып ята, ике ат әзер иде инде.

— Һай, әфәндем, сезне күрүемә шундый шатмын! — диде Планше, д'Артаньянны күргәч.

— Нәрсә бар соң, Планше? — дип сорады егет.

— Сез хуҗабыз Бонасье әфәндегә ышанасызмы?

— Минме? Тамчы да ышанмыйм.

— Алайса, бик яхшы, әфәндем.

— Нигә сорыйсың әле син аны?

— Чөнки сез аның белән сөйләшкән чакта, сүзегезне ишетмәсәм дә, үзегезне күзәтеп тордым. Беләсезме нәрсә, әфәндем: аның ике-өч мәртәбә чырае үзгәреп китте.

— Чынлапмы?

— Сез, әфәндем, аны сизмәдегез, чөнки теге хат турында уйлый идегез. Ә мин, киресенчә, ул хатның бик сәер рәвештә безнең йортка килеп керүенә борчыла идем, шуңа күрә аның кыяфәтен бер генә минут та күздән ычкындырмадым.

— Нинди булып күренде соң ул сиңа?

— Хыянәтче кыяфәте төсле булып күренде.

— Чынлапмы?

— Өстәвенә әле, әфәндем, сез аның белән саубуллашып, чаттан борылып китүгә үк, Бонасье тиз генә эшләпәсен алып, ишеген бикләде дә урам буйлап икенче якка йөгерде.

— Чыннан да хак сүз сөйлисең, Планше: бу хәлләр миңа да бик шикле кебек тоела, тик син бер дә борчылма: бөтенесе тәмам аңлашылып бетмичә, без аңа фатир хакы түләмәячәкбез.

— Һаман шаяртасыз сез, әфәндем, менә сабыр итегез әле — үзегез дә күрерсез.

— Нишләмәк кирәк, Планше, күрәсене күрми калмабыздыр инде!

— Алайса, кич йөрергә чыгуны куеп тормыйсызмы инде, әфәндем?

— Киресенчә әле, Планше, Бонасьега ачуым катырак булган саен, сезне борчый торган хатта әйтелгән төшкә күрешергә дәртләнебрәк барам мин.

— Әй, әфәндем, әгәр сезнең ул карарыгыз...

— Катгый, дустым. Шулай итеп, сәгать тугызга шушында, казармада әзер булып тор. Мин сине алырга керермен.

Хуҗасын уйлаган ниятеннән берничек тә кире күндереп булмавын күргәч, Планше авыр сулап куйды да өченче атны чистартырга кереште.

Асылда ярыйсы ук сак егет булган д'Артаньянга килгәндә исә, ул, үенә кайтасы урында, иң авыр чакларында дүрт дусны шоколад белән сыйлаган Гасконь побына төшке ашка китте.

## XXIV

## ПАВИЛЬОН

Сәгать тугызда д'Артаньян гвардия казармаларына килгәндә Планше инде әзерләнеп беткән, көтеп тора иде. Дүртенче ат та килеп җиткән иде.

Планше үзенең мушкеты һәм пистолет белән коралланган иде.

Д'Артаньян кылычын алган, биленә ике пистолет кыстырган иде. Алар атларына атланып, тавышланмый гына чыгып киттеләр. Төне бик караңгы иде, аларның китүен күрүче-сизүче булмады. Планше хуҗасыннан ун адым чамасы арткарак калып барды.

Д'Артаньян яр буеннан узды, Конферанс капкасы аша үтеп, Сен-Клуга бара торган юлдан китте. Ул заманнарда бу юл хәзергедән күп өлеш матуррак иде.

Шәһәр эченнән узган чакта Планше хуҗа әфәндесеннән тиешле ара саклап арттанрак барды, әмма юлда кеше сирәгәя һәм төн караңгысы куера барган саен ул хуҗа әфәндесенә якыная төште, шулай итеп, Булонь урманына килеп кергәндә ул инде бик табигый рәвештә егет белән янәшә атлый иде. Яшерен-батырын түгел: биек-биек агачларның чайкалып торуы һәм караңгы агачлыклар эчендә ай шәүләсе чагылгалап китүе Планшеның күңеленә шом сала башлаган иде. Хезмәтчесенең тынычсызлануын д'Артаньян да сизде.

— Ни булды болай сезгә, Планше әфәнде? — дип сорады ул.

— Әфәндем, урман чиркәүгә охшый дип уйламыйсызмы сез?

— Кай ягы белән охшый соң ул, Планше?

— Анда да, монда да кычкырып сөйләшеп булмый.

— Нигә кычкырып сөйләшеп булмый, Планше? Куркасыңмы әллә?

— Әйе, әфәндем, безне ишетмәгәйләре дип куркам.

— Безнең нәрсәбезне ишетсеннәр! Безнең сөйләшүебездә берничди дә ярамаган нәрсә юк бит, Планше дустым, шулай булгач, беркем бернинди дә начарлык тапмас иде аннан.

— Һай, әфәндем! — диде Планше, төп фикеренә яңадан кайтып.— Беләсезме, шул Бонасьеның кашларында ниндидер хәйләкәрлек бар, аннары иреннәрен шундый ямьсез итеп кыймылдата!

— Ни шайтаныма дип искә төшердең әле син шул Бонасьены?

— Әфәндем, кеше ул теләгәнен түгел, күңеленә килгәнен исенә төшерә.

— Син куркак булганга шулай ул, Планше.

— Сак булуны куркаклык белән бутарга ярамый, әфәндем.. Саклык ул — яхшы сыйфат.

— Син инде яхшы сыйфатлы — шулаймы, Планше?

— Әфәндем, әнә тегендә нәрсә ялтырый ул? Мушкет көпшәсенә охшаган. Башыбызны имикме?

— Чыннан да, бу тинтәк минем күңелгә дә курку салмагае,— дип сөйләнеп куйды д'Артаньян, де Тревиль киңәшләрен исенә төшереп.

Атын кызу гына юрттырып китте.

Планше, хуҗа әфәндесенең күләгәсе сыман, нәкъ ул эшләгәннәрне кабатлады һәм шундук аның белән тигезләште.

— Әфәндем, әллә без төн буе барачакбызмы? — дип сорады.

— Юк, Планше, син килеп җиттең инде.

— Ничек ул — килеп җиттем? Ә сез, әфәндем?

— Мин тагын берничә адым атлыйм әле.

— Минем үземне генә калдырасызмыни монда?

— Куркасыңмы әллә, Планше?

— Юк, курыкмыйм, әфәндем, тик шуны гына әйтәсем килә: төн бик салкын булачак, ә салкын ревматизмны кузгата. Ревматизмлы хезмәтче начар булышчы инде ул, бигрәк тә сезнең эше җитез хуҗа өчен.

— Ярый, яхшы, Планше, туңа башласаң, әнә тегендәге мәйханәләрнең берсенә керерсең, иртәнге сәгать алтыда мине шунда ишек төбендә көтеп торырсың.

— Әфәндем, бүген иртән сез биргән экюны мин бик зур ихтирам белән ашап-эчеп бетердем, шуна күрә, туңа-нитә калсам, кесәмдә бер тиен дә акчам юк.

— Менә мә ярты пистоль. Иртәнгә хәтле сау булып тор.

Д'Артаньян, атыннан төшеп, тезгенне Планшега ташлады да, плащына төренеп, тиз-тиз китеп барды. Хуҗа әфәндесе күздән югалу белән, Планше:

— Алла, нинди салкын! — дип кычкырып әйтеп куйды. Һәм, тизрәк җылынырга тырышып, шундук тыштан шәһәр читендәге мәйханәләргә хас бизәкләр белән бизәлгән бер йортның ишеген барып шакыды.

Ул арада д'Артаньян, кечкенә бер юлга төшеп, Сен-Клуга барып җитте; ләкин монда килгәч тә үзәк урамнан китмәде, замокны әйләнеп узды да кечерәк бер аулак тыкрыкка барып җитте һәм озакламый хатта әйтелгән павильон каршына килеп чыкты. Павильон бик тын, аулак бер урында иде. Тыкрыкның бер ягында биек дивар калкып тора, павильон әнә шул дивар янында иде, тыкрыкның икенче ягындагы кечерәк бер бакчаны, узган-барганнар кермәсен дип, читән белән киртәләп алганнар, бакчаның түрендә ярлы гына бер алачык бар иде.

Д'Артаньян вәгъдәләшкән урынга килеп җитте дә, килгәнлеген берәр ничек белгертергә дип сөйләшенмәгәнлектән, көтеп тора башлады.

Бөтен тирә-юнь тирән тынлыкка чумган, башкаладан йөз лье ерак киткәнсең дип уйларлык иде. Егет як-ягына каранды да читәнгә сөялде. Бу читәннән, бакчадан, теге алачыктан ары куе томан үзенең итәкләре белән иксез-чиксез җирне каплап-томалап алган, анда берничә ут ноктасы гына елтырап күренгән җәһәннәм упкыны — буш Париж йокыга талган иде.

Әмма д'Артаньянга күз алдындагы һәммә нәрсә ягымлы-ямьле булып күренде, аның күңеленә килгән һәр уй елмая, бөтен караңгылык үтәли яктырып күренә, чөнки озакламый аларның күрешер-кавышыр сәгатьләре җитәргә тиеш иде.

Чыннан да, беравыктан Сен-Клу манарасындагы чаң салмак кына даң-доң итеп ун тапкыр сукты.

Төн уртасында иңрәп таралган бу җиз авазда ниндидер яман бер шом бар сыман иде.

Ләкин чанның һәр суккан авазы — аларның һәркайсы зарыгып көткән вакытның бер кисәге иде бит — егетнең йөрәгендә матур көй булып яңгырады.

Д'Артаньянның күзләре дивар янындагы кечкенә павильонга төбәлгән, павильонның исә, икенче каттагы бер тәрәзәсеннән башка, барлык тәрәзәләре дә капкач белән томаланган иде.

Капланмый калган әлеге тәрәзәдән, койманың теге ягында җәелеп үскән берничә юкә агачының яфракларын көмеш төсенә манып, йомшак кына яктылык сирпелә. Рәхәт, йомшак нурлы кечкенә тәрәзәнең эчендә егетне чибәр Бонасье ханым көтеп торганлыгы тәгаен иде.

Д'Артаньян, шундый татлы уйларга бирелеп, бу бәләкәй генә матур йортка күзен текәгән хәлдә, бернинди сабырсызлык күрсәтмичә, ярты сәгать чамасы көтеп торды; тыштан күренгән алтынлаган кәрнизе белән түшәменең бер өлеше павильонның башка җиһазлары да бик нәфис, зиннәтле булырга тиешлеген белгертеп тора иде.

Сен-Клу манарасындагы чаң унберенче яртыны сукты.

Бу юлы инде д'Артаньян тамырларыннан үзе дә аңлата алмаслык ниндидер бер калтырау узганлыгын тойды, хәер, бәлки, ул туңа башлагандыр да саф физик тойгыны җан тоюы дип аңлагандыр.

Шуннан соң аның күңеленә: хатны ялгыш укыганмын, күрешү вакыты сәгать унбердә булырга тиеш, дигән уй килде.

Тәрәзәгә якынрак килеп, ут яктысына басты, кесәсеннән хатны алып укып карады; юк, ялгышмаган: күрешү вакыты чыннан да сәгать унга билгеләнгән иде.

Егет баягы урынына кире барып басты; мондагы аулак бер тынлык аның күңеленә беркадәр шом сала башлады.

Сәгать унберне сукты.

Д'Артаньян шикләнә-шөбһәләнә үк башлады: чыннан да, Бонасье ханымга әллә бер-бер хәл булды микән?

Егет, гашыйклар гадәтенчә, кулын өч тапкыр шапылдатып

та карады; әмма җавап бирүче булмады, хәтта үзе шапылдаткан тавыш та кире кайтып ишетелмәде.

Шуннан соң ул, беркадәр ачуы килеп: «Бәлки, Бонасье ханы мине көтә-көтә йоклап киткәндер»,— дип уйлады.

Дивар янына килеп, шунда менмәкче булды, ләкин диварны өр-яңадан штукатурлап чыккан булганнар, д'Артаньян тырнакларын авырттырып юкка гына тырмашып азапланды.

Шул чагында ул ут яктысында яфраклары һаман да көмеш төсенә манчылып күренгән агачларга игътибар итте: аларның берсе юл өстендә калкып тора иде. Шул агач башына менеп карасаң, павильонның эчен күреп була бит, дигән уй килде егетнең күңеленә.

Агач башына менүе әллә ни кыен түгел иде. Өстәвенә, д'Артаньянга әле егерме генә яшь, шулай булгач, ул малай чагындагы кайбер гадәтләрен онытып бетермәгән иде. Егет бер тын эчендә агач башына менеп тә җитте һәм яп-якты пыяла аша бүлмә эчен күрде.

Д'Артаньянның күз алдында коточкыч бер күренеш пәйда булды, егетнең тәннәре чирап-чымырдап китте. Йомшак кына булып сирпелгән лампа яктысы биредә коточкыч туздыру, тар-мар итү булганлыгын күрсәтеп тора иде: тәрәзәнең бер пыяласы ватылган, бүлмәнең ишеге каерып ташланган, ишекнең ике ягы да тупсаларында гына асылынып тора; өстәлдә бик нәзакәтле итеп аш-су хәзерләп куелган булган, ахры — анысын идәнгә әйләндереп каплаганнар; паркетта шешә ватыклары, изелгән-сытылган җимешләр чәчелеп ята; бүлмә эчендәге бөтен тамаша рәхимсез, каты көрәш булганлыгын әйтеп тора иде; д'Артаньянга хәтта бу ис-акыл китәрлек тәртипсезлек эчендә умырылган-ертылган кием кисәкләре һәм эскәтер белән пәрдәләрдә берничә кан табы да күренә кебек тоелды.

Йөрәге дөп-дөп сикергән хәлдә тиз генә җиргә төште; бу вәхшәтнең тышта да берәр билгеләре калмадымы икән дип тикшереп карыйсы килде.

Төнге тын караңгылык эчендә һаман да тоньк кына булып йомшак якты сирпелеп тора иде. Шул вакыт д'Артаньян бер нәрсәгә игътибар итте, ул аны башта ук күрмәгән, чөнки моңарчы әле алай җентекләп карарлык сәбәп булмаган иде: җирдә бер урында, тапталып беткән төштә, аннары актарылган икенче бер төштә кеше аягы һәм ат тоягы эзләре бар иде. Моннан тыш, Париждан килгән булырга тиешле экипажның тәгәрмәчләре йомшак балчыкта тирән эз калдырып павильонга хәтле килгән дә яңадан Париж ягына таба борылган иде.

Д'Артаньян, тикшерә торгач, дивар буеннан аерып ташланган хатын-кыз перчаткасы да тапты. Перчатканың былчыракка буялмаган җирләре бик нәфис, чиста иде. Бу — гашыйк егетләр сөяркәләренең нәфис кулыннан йолкып ала торган, исле май сөрткән перчаткалар ишеннән иде.

Д'Артаньян күбрәк тикшергән-караган саен, маңгаена салкын тир чыга барды, биредә бик яман-коточкыч бер хәл булганлыгын уйлап йөрәге кысылып-кысылып куйды, сулышы ешайды, шулай да күңелен тынычландырыр өчен егет үзалдына сөйләнә башлады: бәлки, бу павильонның Бонасье ханымга бернинди катнашы да юктыр әле, яшь ханым аның белән шушы павильонның эчендә түгел, бәлки аның янында гына күрешергә дип вәгъдәләшкән булгандыр, бәлки, ул Парижда эше булып яисә иренең көнчелеге аркасында тоткарланып калгандыр.

Әмма кайвакыт безнең бөтен барлыгыбызны биләп алып, башыбызга коточкыч бер бәхетсезлек килүен кычкырып әйтеп тора торган күңел сизенүе әлеге дәлилләрне җимерә-вата, юкка чыгара иде.

Һәм шуннан соң д'Артаньян акылыннан язган бер кеше кебек булды, чаба-чаба олы юлга чыгып, бирегә килгән юлы белән кире йөгереп китте дә, паромга җитеп, паром йөртүчедән сорашырга кереште.

Кичке сәгать җиделәр тирәсендә паромчы елга аша бер хатынны чыгарган булган икән. Хатын, үзен танытмас өчен булса кирәк, кара япанчага төренгән булган; әнә шундый махсус саклану чаралары кулланганга күрә дә паромчы аңа игътибар итәргә мәҗбүр булган, хатынның яшь һәм чибәр булуын искәреп калган.

Хәзерге кебек, ул заманда да чибәр, яшь хатыннарның күбесе, үзләрен танытмаска тырышып кына, Сен-Клуга барып йөргәннәр. Әмма д'Артаньян паромчының тәгаен Бонасье ханымны күргәнлегенә бөртек тә шикләнмәде.

Паромчы алачыгы эчендәге лампа яктысында егет Бонасье ханымның хатын тагын бер тапкыр укып карады һәм үзенең ялгышмавына, күрешү урыны башка җирдә түгел, нәкъ шушы Сен-Клуда, бүтән урамда булмыйча, д'Эстре әфәнде павильоны янында икәнлегенә ышанды.

Болар барысы да д'Артаньянга күңеле алдамаган, дөрес сизенгән икәнлеген һәм зур бер бәхетсезлек булуын әйтеп тора иде.

Шуннан соң ул кире йөгерде; ул югында павильонда берәр яңа хәл булгандыр да кайтуына нindидер мәгълүматлар булыр кебек тоелды.

Теге тыкрыкта баягыча ук кеше әсәре күренми, тәрәзәдән дә тын гына, йомшак кына булып шул ук лампа яктысы сирпелеп тора иде.

Шул чагында д'Артаньян кинәт теге утсыз-өнсез алачыкны исенә төшерде; ул алачык, һичшиксез, нәрсәдер күргән булырга тиеш, бәлки, сөйләп тә бирер әле.

Ян капкасы бикле иде, егет читән аша гына сикереп төште дә, бәйдәге этнең һаулап өрүенә карамастан, алачык катына килде.

Ишеген шакыды. Башта җавап кайтаручы булмады. Алачык

эче, павильондагы шикелле үк, ниндидер бер кабер тынлыгына чумган иде; әмма бу алачык инде егетнең соңгы өмете иде, шуңа күрә д'Артаньян ишекне шакый бирде.

Озакламый эчтә, ишетмәгәйләре дип шүрләгән сыман, курка-курка гына кыштырдаган бер тавыш ишетелде.

Шуннан соң д'Артаньян ишекне шакуыннан туктады да утенеп сорый-сораша башлады — егетнең тавышыннан шулкадәр борчылу-хафалануы, вәгъдә-өмет, куркуы һәм ялваруы сизелеп тора — андый тавыш иң куркак кешене дә тынычландырыр иде. Ниһаять, искереп чери башлаган тәрәзә капкачы ачылып китте дә, дөресрәге, ачыла төште дә, почмакта янып торган кечкенә генә лампаның тонык нуры д'Артаньянның җилкә каешын, кылыч сабын һәм пистолет сапларын яктыртуга, шундук кире ябылды. Шул бик аз гына арада да д'Артаньян бер карт кеше башын күреп калды.

— Алла хакы өчен, тыңлагыз әле мине! — диде егет.— Мин бер кешене көтә идем, ә ул һаман юк. Борчылуымнан җанымны кая куярга белмим. Әйтегез әле: бу тирәдә бер-бер бәхетсезлек булмадымы?

Кечкенә тәрәзә тагын әкрен генә ачылды, һәм тәрәзәдә тагын әлеге кеше күренде; тик бу юлы аның йөзе баягыдан да катырак агара төшкән иде.

Д'Артаньян ихлас күңеленнән картка бөтенесен сөйләп бирде, тик исемнәрен генә атап әйтмәде; бер яшь ханым белән шушы павильон янында күрешергә дип сүз куешкан булуларын, көтеп-көтеп тә ханым килмәгәч, агач башына менеп, лампа уты яктысында туздырып, тар-мар китереп ташланган бүлмә эчен күргәнлеген сөйләп бирде.

Карт, әйе-әйе дигәндәй баш каккалап, аны игътибар белән тыңлап торды; д'Артаньян сөйләп бетергәч инде, карт бернинди яхшылык өмет иттермәслек бер төс белән башын чайкады.

— Сез нәрсә әйтергә телисез? — диде д'Артаньян кычкыра төшебрәк.— Алла хакы өчен, моның мәгънәсен аңлатып бирегез әле!

— Ай әфәндем, миннән берни сорашмагыз, чөнки күргәннәремне сезгә сөйләсәм, миңа бер-бер яманлык булмый калмас.

— Димәк, сез нәрсәләрдер күргәнсез? — дип сорады д'Артаньян.— Алай булгач, алла хакы өчен күргәннәрегезне сөйләгез әле, дворян буларак ант итеп әйтәм — сезнең һәр сүзегезне сер итеп тотармын,— диде егет, картка бер пистоль акча ташлап.

Карт, д'Артаньянның чыраеннан шулкадәр дә ихласлыгын һәм кайгыруын күреп, тыңлагыз дип ым какты да әкрен генә сөйләргә кереште:

— Сәгать тугызлар тирәсендә урамда ниндидер тавыш ишеттем. Ни хикмәт икән бу? дип ишеккә килеп карасам — берәү бакчама кереп маташа. Мин инде ярлы кеше, талауларыннан курыкмыйм, шуңа күрә ишекне ачтым, берничә адымда

гына өч кеше күренде. Караңгыда җигүле карета белән җайдак атлары да күренә иде. Атлары дворян кыяфәтендә киенгән ирләрнеке булгандыр.

«Ни кирәк сезгә, мәрхәмәтле әфәнделәр?» — дип сорадым мин болардан.

«Синең баскычың булырга тиеш»,— диде башлык сыманнары.

«Әйе, әфәндем, агачтан җимеш җыя торган баскычым бар»,— дидем.

«Син аны безгә бир дә өеңә кереп кит,— ди.— Борчыганыбыз өчен менә сиңа бер экю акча,— ди.— Тик бел аны: әгәр дә мәгәр күргәнең, ишеткәнең турында берәр сүз ычкындырсаң,— мин беләм: сине нихәтле куркытсаң да, син барыбер күреп, ишетеп торачаксың,— ди,— менә шул күргәнең, ишеткәнең турында берәр сүз ычкындырсаң — башың бетәчәк!» — ди.

Шулай дип ул кеше миңа бер экю акча ташлады да баскычны алып китте.

Мин, аның артыннан капканы ябып калгач, өйгә кереп киткән булдым, чынында арткы ишектән чыктым да караңгыда кача-поса гына әнә теге аю баланы төбенә барып бастым — шул төштән бөтенесен карап-күреп тордым.

Өч ир шыпырт кына каретаны якынрак китерделәр дә аннан чәче чалара башлаган тәбәнәк буйлы юан гына бер кешене төшерделәр — өстенә шактый тузган кара кием кигән иде анысы. Курка-курка гына баскычтан менеп, сагаеп кына бүлмә эченә карады бу, аннары иплэп кенә кире төште дә, пышылдап: «Шул үзе»,— диде.

Минем белән сөйләшкәне шундук павильон ишегенә килде,— кесәсеннән ачкыч алып, ишекне ачты да аны артыннан ябып кереп китте; ул арада калган икесе баскычтан менеп киттеләр. Теге карт карета ишеге янында басып калды, кучер карета атларын, хезмәтче исә җайдак атларын тотып торды.

Шул вакыт павильон эченнән каты-каты кычкырган тавышлар ишетелде, ниндидер бер хатын тәрәзәгә йөгереп килде дә, сикерергә җыенган кебек, аны ачып җибәрде. Теге ике ирне күрү белән кире чигенде, ә ирләр бүлмә эченә сикереп төштеләр.

Шуннан соң мин калганнарын күрмәдем, урындык-өстәл ватылган тавыш кына ишеттем. Теге хатын, үзен коткарырга кешеләр чакырып, бераз кычкыргалады да тынды. Өч ир тәрәзәгә килделәр. Икесе, хатынны күтәреп, баскычтан төштеләр дә аны каретага кертеп утырттылар; тәбәнәк буйлы карт та аның артыннан каретага керде. Павильонда калган ир тәрәзәне бикләде, бераздан соң ишектән килеп чыкты; ике юлдашы, атларына атланып, аны көтеп торалар иде. Хатынның каретада икәнлегенә ышангач, ул да иярен атланды, хезмәтчеләре кучер янына утырды. Аннары инде өч атлы сак астында карета

тиз генә китеп тә барды. Шуннан ары мин берни күрмәдем дә, ишетмәдем дә.

Д'Артаньян, бу коточкыч хәбәр тәэсиреннән тетрәнеп, сүзсез-өнсез калып басып торды: егетнең йөрәгендә ачу-ярсу һәм көнчелек ялкыны кайный иде.

Аның бу халәте аһ-зар ору һәм күз яшьләре түгүгә карaганда да картка көчлерәк тәэсир итте, ахры:

— Әфәндем, ихластыр, ул кадәр үк кайгырырга кирәкмәс. Сезнең сөйгәнегезне үтермәделәр бит алар — исән булгач ярый инде,— диде.

— Сез якынча гына булса да әйтә алмассызмы: бу җәһәннәм экспедициясенә нинди дирәк кеше җитәкчелек итте? — дип сорады д'Артаньян.

— Юк шул, мин ул кешене белмим.

— Сез инде ул кеше белән сөйләшкәч, аны күргәнсез, димәк.

— Ә-ә, сез аны нинди дирәк кыяфәтле иде дип сорыйсызмы?

— Әйе.

— Озын гына буйлы, кара тутлы, ябык кына кеше, мыегы кара, күзләре дә кара, киеме белән дворянга охшаган.

— Әһә, шул үзе! — кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян.— Тагын шул кеше! Ул минем газраилемдер! Ә икенчесе?

— Кайсысы?

— Тобәнәге?

— О, анысы бай кеше түгел, анысы тәгаен. Ул кешенең кылычы да юк иде, башкалары аның белән сөйләшкәндә берниндди ихтирам күрсәтмәделәр.

— Берәр лакейдыр,— дип сөйләнеп куйды д'Артаньян.— Һай, бичаракаем, бичаракаем! Нишләттеләр икән инде аны?

— Сез мине фаш итмәскә сүз биргән идегез бит,— диде карт.

— Вәгъдәмне яңадан кабатлап әйтәм. Борчылмагыз — мин дворян. Дворянның сүзе бер генә төрле булыр, мин аны сезгә әйттем инде.

Д'Артаньян, кайгысыннан җанын кая куярга белмичә, яңадан паромга китте. Вакыт-вакыт ул әлеге карт әйткән хатынның Бонасье ханым булуына ышанмый башлый, иртәгә үк аны Луврда күрергә өметләнә; вакыт-вакыт күңеленә, бәлки, аның икенче берәү белән интригасы килеп чыккандыр да көнче мәгъшугы аны эләктереп урлап киткәндер, дигән уй да килә. Егет ничек дип гөман кылырга да белми, газаплана-интегә, бөтенләй өметләрен җуя иде.

— Эх, янымда дусларым булса! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян.— Һич югы, аны эзләп табарга аз-маз өметем булыр иде. Дусларымның үзләренең язмышы да билгеле түгел бит әле!

Инде төн урталары җитеп килә; хәзер Планшены эзләп табарга кирәк иде. Д'Артаньян аз гына уты булган барлык

мәйханәләрне шакып чыкты,— тик берсеннән дә Планшены таба алмады.

Инде алтынчы мәйханәгә кергәч, д'Артаньян болай эзләп йөрүдән мәгънә юк дигән фикергә килде. Ул бит хезмәтчесенә иртәнге алтыда гына үзен көтәргә кушкан иде, хәзер кайда булса да шулай итәргә хакы бар иде аның.

Өстәвенә, егетнең башына, әлеге хәл булган тирәдә калсам, бу серле вакыйга турында кайбер мәгълүматлар кулга төшерүем ихтимал, дигән уй да килде. Шулай итеп, алтынчы мәйханәдә д'Артаньян, әйткәнебезчә, тоткарланып калды, бер шешә иң яхшы шәраб сорап алды да, иң караңгы почмакка урнашып, иртәнгә хәтле шунда утырырга булды, тик бу юлы да өмете акланмады аның, бик игътибар белән тыңлап утырса да, мондагы мастеровой, лакей һәм ломовойларның карганү, шаяру һәм сүгенү сүзләреннән башка, урланган бичара хатынның эзенә төшәргә ярдәм итәрдәй бернәрсә дә ишетә алмады. Шулай итеп, ул, эче пошканнан һәм башкаларга шикле булып күренмәс өчен, шешәсен эчеп бетереп, почмагында җайлабрак урнашырга да йокыга китәргә мәҗбүр булды. Хәтерләвебезчә, д'Артаньянның хәзер егерме яшьлек чагы, бу яшьтә исә йокы дигәнең иң тынгысыз йөрәкләргә дә үзенең көчен күрсәтә.

Иртәнге сәгать алтылар тирәсендә уянып киткәндә д'Артаньянның, гадәттә төнне начар уздыргандагы кебек, кәефе бик начар иде. Әллә ни озаклап җыенасы булмады аның: йоклаган чагымда кесәләрне чистартып китмәгәннәрме дип үз-үзен капшап карады, йөзеге бармагында, акча янчыгы кесәсендә, пистолетлары билендә икәнлеген күргәч, торып, шәраб хакын түләде дә хезмәтчесен иртән табуы җиңелрәк булыр дигән өмет белән чыгып китте. Чыннан да, күксел юеш томан аша аның беренче күргән кешесе Планше булды. Ул кечкенә генә, ярлы гына бер мәйханә ишеге төбендә, ике атны тезгеннәреннән тотып, хуҗа әфәндесен көтеп тора иде. Кичә д'Артаньян, бу мәйханәнең барлыгын да искәрмичә, аның яныннан үтеп киткән булган икән.

## *XXV*

## *ПОРТОС*

Д'Артаньян, туп-туры өенә кайтып китмичә, де Тревиль әфәнделәр ишеге төбендә атыннан төште дә ашыга-ашыга баскычтан йөгереп менеп китте. Бу юлы инде ул аңа хәлне чәчмитүкми сөйләп бирергә булды. Де Тревиль әфәнде, һичшиксез, егеткә әлеге хәл уңаеннан акыллы киңәш бирер; моннан тыш, де Тревиль әфәнде көн саен королеваны күрә, үзенең хакимәсенә турылыклы булганы өчен җәбер күрүче бичара хатын ту-

рында, бәлки, ул олуг ханымнан берәр мәгълүмат белешә алыр.

Де Тревиль әфәнде егетнең сөйләгәннәрен җитди бер төс белән тыңлап торды, аның бу кыяфәте әлеге маҗарадан мәхәббәт интригасына караганда зуррак нәрсә күрүен әйтеп тора иде. Д'Артаньян сөйләп бетергәч:

— Һм...— дип куйды де Тревиль әфәнде.— Монда эшнең кардинал хәзрәтләре катнашыннан башка булмаганлыгы тәгаен.

— Нишләргә соң инде? — дип сорады д'Артаньян.

— Хәзергә бернәрсә дә эшләргә кирәкми, әйткәнемчә, мөмкин кадәр тизрәк Париждан китәргә генә кирәк. Мин королеваны күрермен, бичара хатынның ничек-ничек юкка чыгуын сөйләп бирермен — королева, әлбәттә, ул хәлне белмидер әле. Минем сөйләгәннәрем аңа тотынырга бер җеп булыр, шуннан, бәлки, сез кайтуга, мин сезгә яхшы хәбәрләр әйтә алырмын. Ышаныгыз миңа.

Д'Артаньян де Тревиль әфәнденең, Гасконь кешесе булса да, вәгъдә бирү гадәте юк икәнен, әмма берәр нәрсә ышандырса инде, вәгъдә иткәненнән дә артыграк эшләвен белә иде. Шулай итеп, егет де Тревиль әфәндегә үткәндәге һәм киләчәктәге яхшылыклары өчен күңеленнән рәхмәт укып баш иде, бу батыр, тәвәккәл егетнең эшләренә турыдан-туры катнашкан мөхтәрәм капитан исә, дусларча аның кулын кысып, д'Артаньянга хәерле юл теләп калды.

Де Тревиль әфәнденең киңәшләрен хәзер үк тормышка ашырырга ниятләп, д'Артаньян Каберчеләр урамына кайтып китте — юлга чемоданын тутыртасы бар иде. Өйгә кайтып җиткәндә ул халаттан килеш кенә ишек төбендә басып торган Бонасье әфәндене күрде. Йорт хуҗасының мәкерле бер кеше икәнлеге турында кичә сак Планше сөйләгәннәр менә хәзер кылт итеп д'Артаньянның исенә төште, шуңа күрә бу юлы инде ул хуҗага игътибар беләнрәк күз салды. Чыннан да, Бонасье әфәнденең хаста кешенеке сыман агарынган чыраенда үт әчесе сытылганлыгын белдереп торган (бәлки, очраклы бер сәбәптәндер) саргылт төстән башка, йөзендәге җыерчыкларының рәвешеннән д'Артаньян ниндидер хыянәтчел һәм хәйләкәр бер чалым сизде. Алдакчы кеше көлгән чагында гадел кеше төсле көлми; ике йөзле монафикъ бәндәнең дә күз яше ихлас күңелле кешенеке шикелле булмый. Һәр фальшь — йөзгә кия торган битлек кенә ул, һәм ул битлек нихәтле генә оста ясалган булмасын — игътибар беләнрәк караганда аны һәрвакыт чын кеше йөзеннән аерып була.

Д'Артаньянга да Бонасье битлек киеп йөри кебек, өстәвенә, битлеге бик җирәнгеч кебек тоелды.

Шуңа күрә ул, әлеге җирәнү тойгысын баса алмыйча, аның яныннан сүз катмыйча гына үтеп китмәкче булган иде дә, Бонасье, кичәге кебек, үзе эндәште

— Алай, алай, егетем, төннәрне әйбәт кенә үткәрәбез, ахры? — дип сөйләнә башлады ул.— Иртәнге сәгать җиде бит инде, шайтан алгыры! Күрәм: сез икенчерәк гадәткә күчкәнсез бугай, башка кешеләр иртән торып өйләреннән чыккан чакта сез өегезгә кайтып кына киләсез.

— Ә менә сезгә карата андый шелтәне әйтеп булмый инде, метр Бонасье,— дип җавап кайтарды егет,— тәртип-низам ягыннан сез инде үрнәк кеше. Хәер, шундый яшь, чибәр хатының барында әллә кайларга китеп бәхет эзләп йөрисе юк шул: бәхет үзе йортыңа килә ул. Шулаймы, Бонасье әфәнде?

Бонасьеның йөзе ашлаган киндер төсле агарынып китте, ул авызын кыйшайтып кына елмайгандай итте.

— Һа, һа, бик шук кеше икәнсез,— диде.— Шулай да, егетем, бүген төн буе кайларда йөрдегез соң, шайтан алгыры? Авыл араларындагы юллар сәйран кылып йөрер өчен бигүк җайлы урын түгел, күрәсең.

Д'Артаньян итекләренә күз салды: итекләре куныч читенә хәтле балчыкка буялган иде, аннары күзе галантерейчының башмагы белән аякларына күчте; алар икесе дә бер үк балчыкта йөргәннәр бит: икесендә дә бертөсле үк балчык таплары иде.

Шунда кинәт д'Артаньянның күңеленә бер уй килде. Чәче чалара башлаган, кара киеме белән лакейга охшаган бу карсак буйлы юантык карт шушы Бонасье үзе булмадымы икән? Ир кеше үзенең хатынын урлашкан.

Шунда д'Артаньянның бу галантерейчыны бугазыннан алып буып үтерәсе килде, шулай да тыелып калды, чөнки, белгәнебезчә, д'Артаньян шактый сак егет иде. Әмма чырае шундый үзгәреп китте — Бонасье куркып артына чигенергә маташты, тик ишекнең ябык ягы турысында торганлыктан, баскан урыныннан әллә ни китә алмады.

— Шаяртасыз сез, хөрмәтлем,— диде д'Артаньян,— күрүемчә, минем итекләр пычрак булса, сезнең башмагыгыз белән оекларыгызга да щетка кирәк. Метр Бонасье, әллә сез дә берәр җирдә маҗара эзләп йөрдегезме? Беләсезме, сезнең яшьтәге олы кешегә, шундый яшь, чибәр хатыны да була торып, алай итү бер дә килешеп бетмәс иде бит.

— Юк ла, берүк алла сакласын,— диде Бонасье,— кичә минем, Сен-Мандега барып, бер асрау хакында белешәсем бар иде,— миңа бик кирәк ул,— хәзер юллар бик начар бит, шунлыктан былчыракка батып кайттым. Менә шуны чистартырга җитешмәдем әле.

Бонасьеның барып кайттым дип шул җирне әйтүе д'Артаньянның шиген ныгыта гына төште. Сен-Манде белән Сен-Клу бер-берсеннән бөтенләй капма-каршы якта булганлыктан әйтте аны Бонасье.

Д'Артаньянның бу гөманы күңеленә беренче юаныч булды. Әгәр дә мәгәр Бонасье хатынының кайда икәнлеген белсә,

димәк, кайбер чаралар кулланып, галантерейчыны сөйләндерергә һәм серен әйттерергә мөмкин. Сүз фәкать әлеге гөманны раска чыгару турында гына бара иде.

— Беркадәр тыйнаксызлыгым өчен мине гафу итегез инде, Бонасье әфәнде,— диде д'Артаньян,— беләсезме, төнне йокламый чыгу бик нык сусата, шуңа күрә минем үлеп эчәсем килә. Миңа бирәр стакан су эчертмәссезме? Күршегезнең шундый кечкенә генә үтенечен дә кире какмассыздыр бит инде.

Д'Артаньян, шулай дигәч, хуҗаның рөхсәтен дә көтеп тормыйча, тиз генә өйгә керде дә урын-җиргә күз йөгертеп алды. Урын-җир таушалмаган иде. Бонасье йокларга ятмаган булган. Димәк, ул өенә әлерәк кенә, моннан бер-ике сәгать элек кенә кайткан; димәк, ул хатынын илткән төшкә кадәр яки, һич югы, беренче почта тукталышына кадәр озата барган.

— Бик зур рәхмәт, метр Бонасье,— диде егет, стаканны эчеп куеп.— Сездән үтенгән нәрсәм шул гына иде. Хәзер үз бүлмәмә кайтып, Планшедан итекләремне чистарттырам, аларны чистартып бетергәч, теләсәгез, сезнең башмакларны да чистартырга җибәрермен аны.

Шулай дип, ул галантерейчыны өендә калдырып чыгып китте. Бонасье әфәнде, егетнең бик сәер рәвештә өйгә кереп чыгуына шаккатып, үз ялганыма үзем буталмадыммы икән? — дип аптырашта калды.

Баскычның өске иДәнендә д'Артаньянга Планше очрады. Ул бик нык куркуга төшкән иде. Хуҗасын күрү белән Планше кычкыра төшеп:

— Һай, әфәндем! Тагын бер яңалык бар! Мин инде сезне түземсезләнеп көтәм,— диде.

— Нәрсә бар? — дип сорады д'Артаньян.

— Сез югында безгә кем килгәнлеген уегызга да китерә алмыйсыз, валлаһи.

— Кайчан ул?

— Ярты сәгать чамасы элегрәк, сез де Тревиль әфәнде янында чакта.

— Кем килде соң? Я, әйт, тизрәк бул.

— Де Кавуа әфәнде.

— Де Кавуа әфәнде?

— Нәкъ үзе.

— Кардинал хәзрәтләре гвардиясе капитанымы?

— Нәкъ шул үзе.

— Мине кулга алырга килгәнме әллә?

— Чырае бик төче булса да, шуның өчен килгәндер кебек тоелды миңа.

— Чырае бик төче иде дисеңме?

— Беләсезме, әфәндем, татлы бал инде менә.

— Чынлапмы?

— Кардинал хәзрәтләре сезгә яхшылык итәргә тели, сезнең Пале-Рояльгә килеп чыгуыгызны үтенә, ди.

— Ә син ни диден соң?

— Ул берничек тә килеп чыга алмый, чөнки өйдә юк, дидем Үзе дә сезнең өйдә юк икәнегезне күреп ышанды.

— Моңа каршы ни диде соң?

— Бүген минем янга килми калмасын, диде. Аннары пышылдап кына әйтте: «Хуҗаңа әйт, кардинал хәзрәтләре аны бик ярата, бәлки, аның киләчәктәге язмышы шушы күрешүгә бәйледер»,— диде.

— Кардинал өчен әллә ни оста корылган тозак түгел бу,— диде егет, көлеп.

— Шуңа күрә мин дә сездән аны, кайтчак, бара алмаганы өчен бик үкенер инде, дидем. Де Кавуа әфәнде: «Кая китте ул?» дип сорагач, «Труага, Шампаньга», дидем. «Кайчан?» дип сорагач, «Кичә кич», дидем...

— Планше, дустым, валлаһи, алтын бәһасы кеше икәнсең! — диде д'Артаньян, аны сүзеннән бүлдереп.

— Беләсезме, әфәндем, әгәр сез де Кавуа әфәндене күрергә теләсәгез, сез теләсә кайчан минем сүземне юкка чыгарып, беркая да китмәдем дип әйтә аласыз, дип уйладым. Ул чагында инде мин ялганчы булып чыгам, мин бит дворян түгел, миңа ялганласам да ярый.

— Ярар, борчылма, Планше, гадел кеше дигән абруеңны югалтмыйсың син: чирек сәгатьтән без юлга чыгып китәбез

— Әфәндем, мин үзем дә әле сезгә нәкъ шундый киңәш әйтергә җыенган гына идем. Сер булмаса, кая китәбез соң?

— Әлбәттә, син де Кавуа әфәндегә әйткәнчә нәкъ киресенә. Хәер, минем Атос, Портос һәм Арамисларның язмышын беләсем килгән кебек, син дә Гримо, Мушкетон һәм Базен хакында тизрәк берәр хәбәр ишетергә телисеңдер.

— Әлбәттә, шулай, әфәндем,— диде Планше,— мин менә хәзер үк чыгып китәргә дә әзермен. Минемчә, шушы минутта безнең өчен провинция һавасы Париж һавасына караганда файдалырак, шуңа күрә...

— ...шуңа күрә әйберләрне җыя башла, Планше, китәбез. Мин, андый-мондый шик тумасын дип, буш кул белән алдан җәяү китәрмен. Синең белән гвардия казармаларында очрашырбыз. Бу хуҗа дигәннән, син хак сүз сөйлисең шикелле, Планше,— чыннан да бик оста алдакчы ул.

— Әһә! Мин берәр кеше турында әйтсәм, минем сүземә ышаныгыз инде сез, әфәндем; мин бит кешенең нинди дигәнен чыраеннан ук таныйм.

Сөйләшенгәнчә, д'Артаньян беренче булып баскычтан төшеп китте. Азактан үз-үзен шелтәләргә туры килмәсен өчен, ул соңгы тапкыр өч дустының квартирларына кереп чыкты; аларданн берниндә хат-хәбәр юк, тик Арамис исеменә генә бик матур вак хәрефләр белән язылган, хушбуй исе сеңдерелгән бер хат килгән иде. Д'Артаньян ул хатны тиешле кешесенә илтеп тапшырырга булды. Бер ун минуттан соң аның янына

гвардия казармаларына Планше да килеп житте. Д'Артаньян вакытын әрәм итмәгән, атын үзе иярләп ята иде.

— Ярый, яхшы, хәзер калган өчесен иярлә дә китәбез,— диде ул, Планше чемоданны иyргә бәйләгәч.

— Икешәр ат булгач, тизрәк барырбыз дип уйлыйсызмы? — дип хәйләкәр бер төс белән сорап куйды Планше.

— Юк, шаян әфәнде,— диде моңа каршы д'Артаньян,— әгәр өч дустыбызны сау-сәламәт тапсак, бу дүрт ат белән өч дустыбызны өйгә алып кайта алабыз.

— Алай булганда юлыбыз бик уңар иде шул,— диде Планше.— Хәер, беркайчан да ходайның рәхим-шәфкатеннән өмет өзеп бетерергә ярамый.

— Амин! — диде д'Артаньян, атына атланып.

Гвардия казармаларыннан чыккач, алар икесе ике тарафка китте: берсе Лавильет заставасы аша, ә икенчесе Монмартр аркылы Парижлан чыгып, Сен-Денида очрашырга тиешләр иде. Бу стратегик маневр икесе тарафыннан да бик төгәл үтәлеп, уңыш белән башкарып чыгылды: д'Артаньян белән Планше Пьерфитка икәү бергә килеп життеләр.

Шунысын да әйтеп китик: көндез Планше төнлә йөрүгә караганда батыррак иде.

Шулай булса да, ул тумышыннан бирелгән саклык-сизгерлеген бер минутка да җуймый иде; Планше беренче сәяхәттә юлыккан бер генә казаны да онытмаган һәм очраган бер кешене дошманы итеп күрә иде. Шул сәбәпле ул әледән-әле башыннан эшләпәсен салып сәлам бирә, д'Артаньян исә, Планшеның болай кирәккә-кирәкмәскә дә якты чырай күрсәтүеннән аны бик кечкенә кешенең хезмәтчесе, ахры, дип уйлауларыннан куркып, каты гына орышкалап та ала иде.

Ләкин Планшеның болай әдәп-хөрмәт күрсәтеп китүе узгынчыларга әллә чыннан да бик ошый идеме, әллә бу юлы д'Артаньянның юлына аркылы төшәр өчен беркемне дә җибәрмәгәннәр идеме — һәрхәлдә, безнең ике сәфәрчебез, андый-мондый мажараларга юлыкмыйча гына, Шантильига җиттеләр һәм беренче сәяхәтләре вакытында кергән Гран-Сен-Мартен кунакханәсенә килеп туктадылар.

Кунакханә хуҗасы, ике запас ат белән хезмәтче иярткән яшь кешене күреп, ишек төбендә якты чырай белән каршы алды. Д'Артаньян, унбер лье җир килгәч, Портос бу кунакханәдә булса-булмаса да, биредә тукталырга бик вакыт дип санады. Аннан ары, килеп кермәс борын мушкетер турында сораша башлау да саксызлык булыр кебек тоелды. Әнә шуларны уйлап, беркем хакында берни сорашмыйча, д'Артаньян атыннан төште. Атларны хезмәтчесенә биреп калдырды да уртак залда утырырга теләмәүче кешеләр өчен билгеләнгән кечкенә бер бүлмәгә керде һәм кунакханә хуҗасына бер шешә иң затлы шәраб белән мөмкин кадәр яхшырак аш китерергә кушты.

Моның белән трактирчының кунагына карата беренче күрүдә үк кузгалган хөрмәте тагы да артып китте.

Шулай итеп, д'Артаньянның кушканнары әкияттәгечә бер җитезлек белән өстәл өстенә килеп утырды.

Гвардия полкы король дәүләтенең иң яхшы дворяннарыннан сайлап җыела иде, шуңа күрә хезмәтчесе һәм бер дигән дүрт ат белән сәяхәт итүче д'Артаньян, мундирының гадилегенә карамастан, биредә һич шик-шөбһәсез көчле тәэсир ясарга тиеш иде. Кунакханә хуҗасы аңа үзе хезмәт күрсәтергә булды; д'Артаньян, бу хәлне күреп, ике стакан китертте дә гәп башлап җибәрде:

— Ягез әле, хөрмәтле хуҗа,— дип ике стаканга да шәраб салды,— мин сезгә шәрабның иң затлысын китерергә кушкан идем, әгәр дә мәгәр мине алдаган булсагыз, ул чагында, валлаһи, үзегезгә зарар гына иткән буласыз, чөнки мин беркайчан да үзем генә эчеп утырырга яратмыйм, шуның өчен сез дә минем белән бергә эчәрсез. Шулай булгач, стаканны тотыгыз да эчеп җибәрәбез. Икебезнең дә күңелебез булсын дисәк, нәрсә өчен эчик соң? Әйдәгез сезнең кунакханәнең эшләре гөрләсен өчен эчәбез.

— Авызыгызга бал да май, галиҗәнап, яхшы теләгегез өчен чын күңелемнән рәхмәтемне белдерәм,— диде хуҗа.

— Тик бу мәсьәләдә сез ялгышып куя күрмәгез,— диде д'Артаньян аның сүзенә каршы,— минем тостымда, сез уйлаганнан бигрәк, үзем өчен яхшылык теләү күбрәктер, шәт. Эше гөрләп барган кунакханәләрдә генә яхшы кунак итәләр бит, ә начар кунакханәләрдә исә берниндн рәт-баш юк, мосафир кеше шундагы җитешсезлекнең корбаны була. Мин менә бик күп сәяхәттә йөрим, өстәвенә, башлыча шушы юлдан йөрим, шуңа күрә барлык трактирчыларның да эшләре гөрләп торуын телим.

— Әйтәм җирле, әфәндем, сезне беренче тапкыр гына күрүем түгел кук тоела,— дип куйды хуҗа.

— Әлбәттә! Мин инде Шантильидан бер ун тапкыр узганмындыр, шул ун тапкырның кимендә өч-дүрт мәртәбәсендә сезгә тукталдым. Туктагыз әле... Әйе шул, моннан ун-унике көн элек кенә биредә булып киткән идем мин. Дусларым — мушкетерларны озата килгән идем. Теләсәгез, хәтерегезгә дә төшереп китәм: шуларның берсе, бер ят кеше беренче булып үзенә кагылгач, шуның белән талашып киткән иде.

— Әйе, әйе, дөрес! — диде хуҗа.— Ул хәлне мин дә бик яхшы хәтерлим. Сез, галиҗәнап, Портос әфәндене әйтәсез түгелме?

— Әйе, минем юлдашымның исеме нәкъ шулай. Йа раббым! Бер-бер бәхетсезлеккә дучар булмадымы ул, хөрмәтле хуҗа?

— Галиҗәнап, аның сәфәрен дәвам иттерә алмавын сез үзегез дә күреп калган булырга тиеш идегез.

— Дөрес анысы, ул безнең арттан куып җитәрмен дип сүз биргән иде бирүен, ләкин без аны шуннан соң күрә алмадык.

— Ул галиҗәнап бездә торып калды.

— Ничек инде? Ул монда калдымыни?

— Әйе, әфәндем, шушы кунакханәдә. Дөресен генә әйткәндә, аның өчен без бик борчылабыз.

— Нәрсәсе өчен борчыласыз?

— Аның кайбер чыгым-тотымнары өчен.

— Анысы өчен генә борчылмагыз! Бер бурычын да түләми калдырмас ул.

— Һай, әфәндем, сез чыннан да минем яраларыма шифалы бәлзәм агызасыз! Без аңар зур гына бурыч биреп тордык. Менә әле бүген иртән табип та әйтте: әгәр дә мәгәр Портос әфәнде миңа акча түләмәсә, синнән түләтәм, чөнки мине син чакырттың, диде.

— Портос яраланганмыни?

— Анысын мин сезгә әйтә алмыйм, әфәндем.

— Ничек инде ул әйтә алмыйсыз? Аның турында сез бөтен кешегә караганда да күбрәк белергә тиешсез бит.

— Анысы шулай, әфәндем, әмма безнең хәлдәге кеше бөтен белгәнен дә сөйләми бит; телең өчен колаксыз калуың ихтимал; дип кисәтеп куйсалар — бигрәк тә.

— Ә миңа Портосны күрергә мөмкинме соң?

— Әлбәттә, мөмкин, әфәндем. Баскычтан икенче катка менәсез дә беренче номерга шакыйсыз. Тик үзегез икәнлеген алдан әйтеп кирәгез.

— Мин икәнлегемне алдан әйтеп керергәмени?

— Әйе, әйе, югыйсә бәлагә таруыгыз ихтимал.

— Сезнеңчә, минем нинди бәлагә таруым ихтимал соң?

— Портос әфәнде сезне минем кешеләрнең берсе дип уйлап, ярсуыннан кылычы белән кадавы яисә башыгызга пуля җибәрүе ихтимал.

— Сез аны нишләттегез соң алай?

— Без аннан акча сораган идек.

— Ах, шайтан алгыры, аңладым хәзер! Акчасы булмаганда Портос андый сүзне бер дә яратмый шул. Минем белүемчә, аның акчасы булырга тиеш иде бит.

— Без дә нәкъ шулай дип уйлаган идек шул, әфәндем. Кунакханәбез бик тәртиптә тотылып, атна саен йомгак ясап барылганлыктан, без аңа атна азагында счет кертеп биргән идек. Күрәсең, бик җайсыз вакытка туры килгәнбездер, чөнки акча хакында авыз ачу белән үк, ул безне пыр туздырып сүгеп чыгарды. Дөрес анысы, алдагы көнне ул шакмак уйнаган иде.

— Ах, шакмак уйнаган! Кем белән уйнады соң ул?

— Ай алла, кем белгән аны! Ниндидер бер узгынчы әфәнде белән, шуңа бер партия ландскнехт уйнарга тәкъдим иткән иде.

— Алайса бөтен хикмәт әнә шунда. Акчасын оттырып бетергәндер, бичара.

— Атына хәтле оттырды, әфәндем, чөнки әлеге ят кеше китәргә җыенган чакта хезмәтчесе Портос әфәнденең атын иярләп маташканын күрдек. Әлеге кешегә шуны искәрткән идек, ул әйтте: кеше эшенә тыгылмагыз, ат минеке, диде. Шундук Портос әфәндегә дә искәрттек. Ул әйтте: дворян кешенең сүзенә ышанмасагыз, сез түбән кеше буласыз, ди, ат минеке дип әйткән икән, димәк, ат аныкы була, ди...

— Сүзеннән үк таныйм Портосны! — дип мыгырданып куйды д'Артаньян.

Кунакханә хуҗасы сөйләвендә дәвам итте:

— Шуннан соң мин аңа әйттем: әгәр инде безгә бурычны түләү хакында сөйләшеп килешергә язмаган икән, ул чагында, рәхим итеп, һич югы, минем иптәшкә — «Алтын Бөркет» хуҗасына күчәрсез, бәлки, дидем. Моңа каршы Портос әфәнде әйтте: «Сезнең кунакханә яхшырак, мин монда калырга телим», — диде. Шулай мактап торгач инде, мин тагын да даулашмадым. Кунакханәмдәге бу иң яхшы бүлмәмне бушатып, дүртенче каттагы әйбәт кенә бер бүлмәгә күчүен үтендем. Бу сүземә каршы Портос әфәнде әйтте: менә-менә хәзер минем сөяркәм килеп җитәргә тиеш, ди, ул король сараендагы иң зур дәрәҗәле ханымнарның берсе, ди. Шулай булгач, сез аңларга тиешсез, ди: хәтта менә әле мин яшәгән бу бүлмә дә ул ханымны каршылар өчен бик фәкыйрь, ди. Әмма, аның сүзләрен хаклы санаган тәкъдирдә дә, мин үземне сүземдә торырга мәҗбүр санадым; ә ул, минем белән бәхәсләшеп тә тормастан, пистолетын чыгарды да ятагы янындагы бәләкәй өстәл өстенә куйды һәм, кем дә кем мина берәр җиргә — икенче бүлмәгәме я булмаса башка кунакханәгәме күчү хакында берәр сүз әйтсә, минем эшемә тыкшынып маташкан ул кешенең башын чәрдәкләп бетерәм, ди. Шул сәбәпле аның янына шуннан бирле, хезмәтчесеннән башка, беркем керми, әфәндем.

— Алайса Мушкетон монда?

— Әйе, монда, әфәндем, китеп биш көн торганнан соң әйләнеп кайтты ул, анысының да бер дә кәефе юк. Ул да юлда чакта күңелсез хәлләргә очраган ахры. Бәхетсезлеккә каршы, ул хуҗасына караганда житезрәк-булдыклырак икән — аның өчен бөтен дөньяның астын өскә китерә: хуҗасына сораган әйберсен бирмәсләр дип, сорамый-нитми, нәрсә кирәк — шуны ала.

— Шулай, — дип куйды д'Артаньян, — мин ул Мушкетонның бик турылыклы, булдыклы егет икәнен гел сизә идем.

— Анысы бик ихтимал, әфәндем, әмма андый турылыклы, булдыклы кеше белән елына өч-дүрт кенә тапкыр эш итәргә туры килсә дә, мине тәмам бөлдереп китәр иде ул.

— Юк, алай түгел, чөнки Портос сезгә бурычын түләми калмас.

Трактирчы, ышанмыйча:

— Һе...— дип кенә куйды.

— Бик зур дәрәҗәле бер ханым ана ягымлы мөнәсәбәт күрсәтә, сезгә түлисе бурыч шикелле вак-төяк аркасында гына ул ханым аны кыен хәлдә калдырмас.

— Әгәр мин ни уйлаганымны әйтергә батырчылык итсәм...

— Нәрсә уйлыйсыз соң?

— Уйлау гына түгел, беләмен дә.

— Нәрсә беләсез?

— Алай гына да түгел — тәгаен беләм.

— Тәгаен нәрсә беләсез? Әйтегез әле.

— Ул бик зур дәрәҗәле ханымның кем икәнен белгәнлегемне әйтеп бирер идем мин сезгә.

— Сез?

— Әйе, мин.

— Ничек белдегез сез аны?

— Ай, әфәндем, әгәр дә сезнең тыйнаклыгыгызга ышана алсам...

— Сөйләгез, сөйләгез, мин сезгә дворян буларак ант итеп әйтәм: миңа ышануыгызга бер дә үкенмәссез.

— Алайса менә шул, әфәндем, үзегез дә беләсездер, борчу дигәнең бик күп нәрсә эшләтә икән ул.

— Нәрсәләр эшләдегез соң?

— Бурыч бирүченең хокукыннан узарлык бернәрсә дә эшләмәдем.

— Шулай да?

— Портос әфәнде безгә шул герцогиняга атап язган хатын бирде дә аны почта белән җибәрергә кушты. Ул чагында хезмәтчесе кайтып җитмәгән иде әле. Аның үзенең бүлмәдән чыгып йөри алмавын искә алсак, бу йомышын ул, теләсә-теләмәсә дә, безгә тапшырырга тиеш иде.

— Шуннан?

— Хатны почта белән җибәрәсе урында,— алай җибәрү бервакытта да ышанычлы түгел,— мин, бер кешебезнең Парижга баруыннан файдаланып, шуңа хатны әлеге герцогиняның үз кулына тапшырырга куштым. Бу бит инде Портос әфәнденең теләгән үтәү дигән сүз, шулаймы? Шул хат өчен бик борчылган иде бит ул.

— Шул чамада.

— Алайса, шул, әфәндем, бик зур дәрәҗәле ул ханымның кем икәнлеген беләсезме сез?

— Юк, минем аның хакында Портостан ишеткәнем генә бар.

— Шул ялган герцогиняның кем икәнен беләсезме?

— Кабатлап әйтәм: мин ул ханымны белмим.

— Шатледан карт кына бер прокурор хатыны, Кокнар ханым икән ул, әфәндем. Ким дигәндә, илле яшь бар инде ул ханымга, җитмәсә әле, көнләшкән булып кылана икән. Миңа шунысы да бик сәер тоелды: үзе бик зур дәрәҗәле ханым — үзе Аю урамында яши.

— Бу кадәресен каян беләсез соң сез?

— Белүем шуннан: хатны алгач, ханымның бик яман ачуы килгән, Портос әфәнде — җилкуар ул, мөгаен, кылыч белән кадаулары берәр хатын-кыз аркасында булгандыр, дигән.

— Аңа кылыч белән кададылармыни?

— Ай алла, нәрсә дим соң әле мин?!

— Портоска кылыч белән кадаганнар, дидегез.

— Анысы шулай шулаен да, бу хакта беркемгә дә сөйләмәскә дип бик ныгытып әйтеп куйган иде бит ул миңа!

— Нигә?

— Нигә, имеш! Чөнки ул, әфәндем, сез киткән чакта талашып калган теге ят кешене аркылы тишеп чыгарам! — дип бик мактанган иде дә киресенчә килеп чыкты — шапырынуына карамастан, теге кеше моның үзен кадап екты. Менә шуннан соң инде Портос әфәнденең кылыч белән кадатканлыгын беркемгә дә белгертәсе килми. Ул бит бу маҗаралары белән үзен кызгандырырга теләгән теге герцогинядан кала бөтен кеше алдында үзен бик горур тота.

— Димәк, шул кылыч белән кадатуы сәбәпле ул һаман урын өстендә ятарга мәҗбүр?

— Әйе, әйтсәм әйтим, бик җилле кадады. Мөгаен, дустыгызның җаны тәненә кадаклап куелгандыр.

— Сез ул хәлне күреп тордыгызмы?

— Кызыксынып артларыннан ияргән идем, сугышуларын карап тордым, тик алар минем үземне күрмәделәр.

— Ничегрәк булды соң ул?

— И, әйтсәм әйтим, озакка бармады ул. Кара-каршы басуга, әлеге ят кеше кылычы белән ялт кына берне соскан иде — Портос әфәнде кире сугып өлгергәнче, аның күкрәгенә өч дюйм озынлыгы тимер кадалды. Ул аркасы белән чалкан ауды. Ят кеше шундук аның күкрәгенә кылыч очын китереп терәде. Аннары инде Портос әфәнде, дошманы каршында чарасыз калганлыгын күреп, бирелергә мәҗбүр булды. Шуннан соң ят кеше аның исемен сорады, исеме д'Артаньян түгел, бәлки Портос икәнлеген белгәч, аны үзенең беләгенә тотындырып, кунакханәгә чаклы китерде дә, атына атланып алып, юкка да чыкты.

— Димәк, ул ят кеше д'Артаньян белән талашырга җай эзләгән?

— Шулай булса кирәк.

— Шуннан соң аның ниләр эшләгәнен белмисезме сез?

— Юк. Минем аны аңарчы да, шуннан соң да бүтән күргәнем булмады.

— Бик шәп. Мин үземә кирәк нәрсәләрнең барысын да белдем. Димәк, Портосның бүлмәсе икенче катта, беренче номер, дидегез, шулаймы?

— Шулай, әфәндем, кунакханәбезнең иң яхшы бүлмәсе, мин инде аңа ун кеше кертеп чыгарган булыр идем.

— Берук борчылмагыз,— диде д'Артаньян көлеп,— Портос сезгә бурычын герцогиня Кокнар акчасы белән түләр.

— Ай, әфәндем, прокурор хатынымы ул, герцогинямы, миңа дисә теләсә кем булсын — тик акча янчыгын гына чишсен. Юк, чишмәс шул, ул ханым ифрат катгый итеп әйткән: Портос әфәндедең акча соравыннан, хыянәтеннән гарык булдым инде, мин аңа бер су да акча бирмим, дигән.

— Сез аның җавабын кунагыгызга әйттегезме соң?

— Юк, әйтмәдек: ул чагында Портос әфәнде үзенең йомышын ничек үтәгәнебезне сизгән булыр иде.

— Димәк, ул әле һаман акча килер дип көтә?

— Хикмәт тә шунда шул: һаман көтә! Әле кичә генә икенче тапкыр хат язып җибәрде, бу юлы инде хатны хезмәтчесе почта белән җибәрде.

— Прокурор хатынын карт һәм ямьсез дисез инде?

— Ким дигәндә, илле яшьләр булыр, әфәндем, Патонның әйтүенә караганда, чибәр дә түгел икән.

— Алайса, тыныч булыгыз: ахыр чиктә ул ханымның күңеле йомшар. Өстәвенә, Портосның сезгә бурычы да әллә ни күп түгелдер.

— Ничек күп түгел? Табипка тиешлесен санамаганда да, егерме пистоль чамасы! Оһо! Нәрсә тели — шуны китертә ул, бик иркен яшәргә өйрәнгәнлеге күренеп тора.

— Аны сөяркәсе ташласа, дуслары табылыр, монысы инде тәгаен. Шулай булгач, бер дә борчылмагыз, хөрмәтле хуҗа, аның хәленә күрә тиешле илтифатны күрсәтегез.

— Әфәндем, сез прокурор хатынын телгә алмаска, ярасы турында да бер сүз әйтмәскә вәгъдә бирдегез бит.

— Ул хакта кабат әйтмәсәгез дә була, мин сүз бирдем бит инде.

— Белсә, мине атып үтерә бит ул!

— Курыкмагыз, алай ук куркыныч кеше түгел ул.

Шулай дип, д'Артаньян, кунакханә хуҗасын бик газиз булган ике нәрсәсе: акча янчыгы белән җаны мәсьәләсендә беркадәр тынычландырып, баскычтан менә башлады.

Өске каттагы, бөтен коридорда башкалардан аерылып торган бер ишеккә кара кара белән зур итеп 1 ле саны язып куелган иде; д'Артаньян ишекне шакыды да, эчтән: «Юлыгызда булыгыз», дигән киңәшне ишеткәч, бүлмәгә керде.

Портос, урында яткан килеш, остару өчен, Мушкетон белән ландскнехт уйный, учак алдында исә тимер шештә кыр тавыгы пешә, зур каминның баш-башында ике кәстрүл кайнап утыра, аннан, борынны кытыклап, кролик фрикасесы исе һәм шәраб соусы белән пешә торган балык исе килә. Бөтен өстәл өсте һәм комодның мәрмәр тактасы буш шешәләр белән тулган иде.

Портос, дустын күрүгә, шатлыгыннан кычкырып җибәрде.

Мушкетон исә, хөрмәт йөзеннән торып, урынын д'Артаньянга бирде дә кәстрүлләрне карарга китте — алар аның махсус күзәтүендә иде, күрәсең.

— Ах, шайтан, сезмени бу?! — диде Портос д'Артаньянга.— Рәхим итегез! Тора алмавым өчен гафу үтенәм. Гафу дигәннән, минем белән нинди хәл булганлыгын беләсезме сез? — диде аннары, беркадәр борчылган төс белән д'Артаньянга карап.

— Юк шул, белмим.

— Хуҗа берни дә сөйләмәдемени?

— Мин аннан сезнең кайда икәнлегегезне генә сорадым да шундук өскә менеп киттем.

Портос иркенрәк сулу алган кебек булды.

— Ә сезгә ни булды соң, Портос дус? — дип сорады д'Артаньян.

— Шул: дошманымны өч тапкыр кылыч белән сыйлап, дүртенчесендә моның эшен бетерим дигәндә генә ташка абынып егылдым да тез башымны тайдырдым.

— Чынлапмы?

— Ант әгәр! Ярый, теге хөрәсәннең бәхете булды, югыйсә мин аны шунда бетергән дә була идем, тәгаен.

— Кая китте соң ул?

— Валлаһи, белмим. Үзенә тигән өлешне алды да, кайтарып тормастан, китеп тә барды. Ә сез соң, д'Артаньян дус, сезнең хәлләр ничек булды?

— Димәк, тайган тез башыгыз сезне урын хастасы итеп яткыра, әйеме, Портос дус? — дип төпченүендә булды д'Артаньян.

— Әйтмәсәгез дә, юк кына нәрсә инде үзе! Хәер, берничә көннән аякка басармын дип уйлыйм.

— Нигә үзегезне Парижга кайтартмадыгыз соң? Монда сезгә коточкыч күңелсездер бит?

— Үзем дә нәкъ шулай итәргә дип җыенган идем. Шулай да мин сезгә кайбер нәрсәләрне яшерми әйтергә тиеш булам, дустым!

— Нәрсә ул?

— Менә нәрсә. Үзегез әйтмешли, миңа чыннан да коточкыч күңелсез булды, аннары, кесәмдә сездән алган җитмеш биш пистоль акчам да бар иде. Менә шуннан, беркадәр күңел ачылып китмәсме дип, узып барышлый гына бирегә туктаган бер дворяннан минем янга менүен үтендем, шакмак уйнарга тәкъдим иттем. Ул риза булды. Шулай итеп, минем кесәдәге җитмеш биш пистоль акча аның кесәсенә күчте. Шуңа өстәп, атны да алып китте. Ә сезнең хәлләр ничек соң, д'Артаньян дус?

— Нишлисең бит инде, Портос дус, һәммә эштә дә уңып булмый шул,— диде д'Артаньян.— Шундый бер мәкальне беләсезме: «Уенда уңмаган — сөюдә уңар»,— диләр. Сөюдә сезнең

эшегез артыгы белән уңа, ә үен әнә шуның каруын кайтара. Андый гына бәла бәламени ул сезгә! Сезнең соң, бәхетле бәндә, герцогинягыз юкмыни? Хәлегезне белгәч, ярдәмгә килми калмас инде ул!

— Әнә шул уенда уңмаганга күрә дә хат язган идем мин аңа, илле луидор акча сораган идем — минем хәзерге хәлемдә ансыз һич мөмкин түгел бит,— диде Портос һичбер уңайсызланусыз.

— Я, ничек булды соң?

— Ничек булсын! Үзенең берәр утарында ахры ул — җавап алганым юк әле.

— Чынлапмы?

— Чынлап, җавап юк. Кичә үзенә янә бер хат язып җибәрдем, тагы да ышандыргычрак итеп. Монда сез дә бар бит әле, дустым, сезнең хакта да сөйләшик әле. Дөресен әйтим: сезнең язмышыгыз өчен мин бераз борчыла да башлаган идем инде.

— Күрүемчә, хуҗа сезгә начар мөнәсәбәт күрсәтми булса кирәк, Портос дус,— диде д'Артаньян, аш тулы кәстрүлләр һәм буш шешәләрне күрсәтеп.

— Юк ла! — диде Портос.— Моннан өч-дүрт көн элек шул оятсыз адәм миңа счет китергән иде, счеты-ние белән бүлмәдән куып чыгардым. Шуннан инде хәзер мин монда җиңүче булып, үзенә күрә бер яулап алучы булып утырам, шуңа күрә, һөҗүм итмәгәйләре дип, баштанаяк коралланып куйдым.

— Шулай да ара-тирә шыпырт кына ауга да чыгып кергәлисез шикелле,— диде д'Артаньян көлеп. Һәм шешә белән кәстрүлләргә бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Бәхетсезлеккә каршы, үзем түгел шул! — диде Портос.— Бу нәләт тез кузгалырга да бирми. Мушкетон ул — тирә-юньне күздән кичереп, азык-төлек табып кайта... Мушкетон, дустым,— диде Портос,— күрәсезме, ярдәмче көч килде безгә, шуңа күрә азык запасын арттыра төшәргә туры килер.

— Мушкетон, сез миңа да бер эштә ярдәм итәргә тиешсез әле,— диде д'Артаньян.

— Нинди ярдәм, әфәндем?

— Планшены да үз әмәлләрегезгә өйрәтегез әле. Дөнья хәлен белеп булмый: минем дә менә шушылай камалышта калуым бар. Сез үзегезнең хуҗагызга яхшы шартлар тудырган кебек, ул да шулай эшләсә, миңа бер дә зарар итмәс иде бит.

— И алла,— диде Мушкетон тыйнак кына итеп,— ул эшнең бер кыенлыгы да юк бит, әфәндем! Бары тик җитез булырга гына кирәк — менә шул. Мин авылда үскән егет, минем әти яшь вакытларында браконьерлык белән шөгыльләнә торган иде.

— Ә калган вакытында нишли иде?

— Кәсепле эш белән шөгыльләнә торган иде. Мин ул кәсепне әле һаман да ярыйсы ук табышлы кәсеп дип саныйм.

— Нинди кәсеп белән шөгыльләнә иде соң?

— Католикларның һугенотлар белән сугышкан чаклары иде. Католикларның һугенотларны, һугенотларның католикларны кыруын һәм боларның барысы дин хакына эшләнүен күреп, безнең әти үзенә католик та, һугенот та була ала торган катнаш бер дин уйлап тапты. Менә шуннан соң ул, җилкәсенә озын авыр мылтыгын асып, юл буендагы киртә куаклары артында йөри торган булды. Ялгызы гына кайтып барган католикны күрүгә, тегенең күңелендә протестантлар дине баш калкыта. Мосафирга мылтыгын төзи бу, аннары, ун адым чамасы калгач, тегенә сүз куша, нәтиҗәдә мосафир кеше, үзенең җанын саклап калу өчен, кесәсендәге янчыгын чыгарып бирергә мәҗбүр була. Билгеле инде, әтигә берәр һугенот очраса, шундук аның күңелендә католик чиркәвенә карата кайнар мәхәббәте уяна, моннан чирек сәгать кенә элек изге динебезгә карата күңелендә ни сәбәптән шик туауын үзе дә аңлый алмый. Әйтсәм әйтим, әфәндем, мин үзем католик, чөнки әтием, үз гадәтен саклап, абыйны һугенот итте.

— Ә дөньядан ничегрәк китте соң ул мөхтәрәм кеше? — дип сорады д'Артаньян.

— Һай, әфәндем, бик бәхетсез язмышка дучар булды ул. Бервакыт ул тар гына сукмакта һугенот белән католик арасына килеп эләгә. Әтинең инде алар белән эш иткәне булган икән, болар моны танып алалар. Әтигә каршы берләшәләр дә аны тотып агачка асалар. Шуннан соң болар, беренче очраган авыл мәйханәсенә килеп, әлеге эшләре белән мактана башлыйлар. Без абый белән нәкъ шул мәйханәдә сыра эчеп утыра идек.

— Ни эшләттегез инде сез аларны? — дип сорады д'Артаньян.

— Башта аларның мактанганнарын тыңлап утырдык, аннары, мәйханәдән чыгып, тегеләр икесе ике якка киткәч, абыем католикның юлы буена посты, ә мин — һугенот юлына. Ике сәгатьтән соң инде тегеләрне хәл иттек, абый үз эшен башкарды, мин — үз эшемне. Шунда без әтинең алдан ук күреп эш итә белүенә сокландык: кирәк булуы бар дип, ул безнең икебезне ике дингә түндергән.

— Хак сөйлисең, Мушкетон, әтиегез бик зирәк егет булган, күрәсең. Ял вакытында шул намуслы кеше браконьерлык белән шөгыльләнә иде, дидегезме әле?

— Әйе, әфәндем, бугалак куярга, кармак салырга ул өйрәтеп калдырды инде мине. Шуңа күрә, бу җүнсез хуҗа безгә начар ашлар ашата башлагач,— андый азык безнеке кебек нәфис карынга түгел, талымсыз корсакка гына ярый шул,— мин әкренләп үземнең иске кәсебемә керештем. Принц урманнарында сәйран кылып йөргәндә болан сукмакларына бугалаклар куя, король буасы яры буенда яткан чакта кармак сала башладым. Менә хәзер, аллага шөкер, күреп торасыз: авыру кешеләргә килешә торган җиңел, тәмле азыкка кытлык

сизмибез — урман тавыгы да, кролигы да, карпы да, елан балыгы да — һәммәсе дә бар.

— Ә шәраб? Шәрабны кем китереп тора соң сезгә? Хуҗа үземе? — дип сорады д'Артаньян.

— Ничек дип әйтергә? Шулай да, шулай түгел дә.

— Ничек инде ул — шулай да, шулай түгел дә?

— Дөрес анысы, китереп торуын тора ул, тик үзе аны эшләгәнен белми.

— Төшендеребрәк сөйләгез әле, Мушкетон, сезнең әңгәмәгез бик гыйбрәтле.

— Ярый, хуш, әфәндем. Сәяхәт итеп, дөнья гизеп йөргән чагымда миңа бер испан очраган иде. Ул бик күп илләрне күргән, шул исәптән Яңа Дөньяда да булган.

— Менә бу өстәл, бу комод өстендә торган шешәләргә ул Яңа Дөньяның ни катнашы бар соң?

— Чак кына сабыр итегез, әфәндем, һәр нәрсәнең үз җае бар.

— Сүзегез хак, Мушкетон, сезгә ышанам, ягез, тыңлыйм.

— Шул испанның Мексикага сәяхәт кылганда ияртеп йөргән бер хезмәтчесе бар иде. Бу хезмәтче минем якташ булып чыкты, без аның белән тиз дуслашып киттек, холыкларыбыз белән дә бер-беребезгә бик охшаган идек. Икебезнең дә дөньяда иң яраткан шөгылебез — ау икән. Ул миңа шундагы җирле халыкның пампасларда ничек итеп юлбарыс, кыргый үгезләрне аулавын сөйләде: гадәттәге элмәкле бау белән алар шул коточкыч җанварларны муеннарыннан чалдырып кына алалар икән. Шулкадәр чос булуга, бауны егерме-утыз адымнан ташлап, теләгән җиргә эләктерә алуга башта мин ышанмаган идем, әмма соңрак ышанырга туры килде. Минем дус шешәне үзеннән утыз адымга куя да бауны ташлаган саен элмәге белән шешәне муеныннан эләктереп кенә ала. Мин дә бик тырышып өйрәнә башладым бу эшне. Табигать биргән беркадәр сәләтем дә булгач, хәзер мин *лассоны* мексиканнардан бер дә ким ташламыйм. Беләсезме — нәрсә? Безнең кунакханә хуҗасының бик бай шәраб базы бар, тик ачкычын ул үзе белән генә йөртә. Әмма подвалның җиллеге бар. Әнә шул җиллектән инде лассо ташлыйм мин. Хәзер мин кайда яхшы урын барлыгын беләм, запасны шуннан гына сосам. Менә, әфәндем, өстәл белән комод өстендәге шешәләргә Яңа Дөньяның әнә шундый катнашы бар. Ә хәзер сез безнең шәрабтан авыз итеп, ихласыгыздан аның хакында фикерегезне әйтмәссезме?

— Рәхмәт, дустым, бик рәхмәт; үкенечкә каршы, мин әле яңа гына ашап-эчеп алган идем шул.

— Ярый алайса, Мушкетон, әйдә табын әзерлә, без ашап-эчкән арада, д'Артаньян ун көн күрешми торган вакытта ниләр күргәнен, ниләр кичергәнен сөйләр,— диде Портос.

— Сөйлим, сөйлим,— диде д'Артаньян.

Портос белән Мушкетон, уртак бәхетсезлек кичергән якын дусларча, авырудан савыгып килүче кешеләр кебек тәмләп кенә ашаган-эчкән арада д'Артаньян аларга Арамисның яраланып Кревкерда калуын, Атосның үзен ялган акча белән эш итүдә гаепләүче кешеләр белән сугышып, Амьенда калуын, үзенең исә, Англиягә барып җитү өчен, граф де Вардның эчен тишәргә мәҗбүр булуын сөйләп бирде.

Ләкин д'Артаньянның ихласлыгы шул төшкә җиткәч бетте; ул Англиядән бик шәп дүрт ат алып кайтуын гына әйтте — берсе үзенә, калганнары өч иптәшенә икән — һәм ахырда Портоска дигән,атының кунакханә абзарында булуын әйтте.

Шул чакны бүлмәгә Планше килеп кереп, хуҗасына: атлар ял итте, Клермонга барып кунарга мөмкин, дип белдерде.

Хәзер инде д'Артаньян Портосның язмышы өчен борчылмый, аның тизрәк барып, калган ике иптәшенең хәлләрен беләсе килә иде, шуңа күрә ул авыру иптәшенең кулын кысып саубуллашты да, тегеләрне эзли барамын, диде. Хәер, ул кайткан чакта да шушы ук юл белән кайтырга исәп итә, берәр атнадан, әгәр Портос аңарчы Гран-Сен-Мартен кунакханәсеннән китеп бармаса, мушкетер дустын үзе белән алып кайтырга уйлый иде.

Портос: мөгаен, бу тиз белән аңарчы китә алмамдыр, дип җавап бирде аңа. Өстәвенә, герцогинясыннан җавап алганчы, Шантильида бераз торып торырга да кирәк иде аңа.

Д'Артаньян дустына тиз арада яхшы җавап килүен теләде, аннары Мушкетоннан Портос турында кайгыртуын тагын бер тапкыр үтенеп, кунакханә хуҗасына акча түләде дә, хәзер инде бер җайдак атыннан арынган Планше белән, барасы юлына кузгалды.

## *XXVI*

## *АРАМИСНЫҢ ДИССЕРТАЦИЯСЕ*

Д'Артаньян Портоска ярасы турында да, прокурор хатыны хакында да бер сүз әйтмәде. Әле яшь булуына да карамастан, безнең Гасконь егете шактый сак кеше иде. Мактанчык мушкетер сөйләгәннәренең барысына да ул ышанган булды, чөнки нинди генә дуслык та серенне фаш иткәнне күтәрмәвен егет белә, әгәр ул сер кешенең горурлыгына кагыла торган булса — бигрәк тә; өстәвенә, без кешенең эчке тормышын белсәк, һәрвакыт анардан билгеле бер әхлакый өстенлек тоеп йөрибез. Шуңа күрә д'Артаньянның, киләчәктәге интригаларның планын корган чакта Атос, Портос һәм Арамисны үз эшендә корал итәргә карар кылып, өч иптәше белән идарә итәсе җепләрне алдан үк кулына җыя башларга да исәбе юк түгел иде.

Әмма тирән бер сагыш, пошыну тойгысы юл буе аның йөрәгенә тынгылык бирмәде: егеткә тугрылыгының әҗерен

кайтарырга җыенган яшь, чибәр Бонасье ханым турында уйланды ул; хәер, шунысын да ачыклабрак әйтеп китик: егетнең йөрәгендәге бу сагыш тойгысы чынга ашмый калган бәхет өчен пошынудан бигрәк, бичара хатынга берәр төрле бәхетсезлек булмагае дип борчылуыннан иде. Ул инде бер дә шикләнми: кардинал хәзер аннан үч ала, Бонасье ханым шуның корбаны иде; белгәнебезчә, кардинал хәзрәтләре, үчексә, бик яман итеп үч ала белә. Д'Артаньян үзе ни сәбәптән министрның җылы карашына лаек булгандыр — егет ул кадәресен белми, гвардия капитаны де Кавуа аны өендә туры китергән булса, шәт, аңлатып та биргән булыр иде моны.

Тирән уйларга чумып, туктаусыз уйланып барсаң, күпме вакыт үткәнен дә, күпме юл узылганын да сизми каласың. Андый чакта кешенең тышкы тереклеге ярым йокыга охшый, уйларың исә төш күрү сыман гына булып тоела. Шул уйлар тәэсирендә вакытның исәбе, араның ераклыгы югала. Сез фәкать бер урыннан чыгып китеп, икенче урынга барып кына керәсез. Үткән кадәр юлыннан хәтердә анык булмаган бер томан гына кала — меңләгән сын-сурәт — агачлар, таулар һәм үзәннәр шәйләнер-шәйләнмәс булып агылып китеп кенә тора. Д'Артаньян, атының үзе теләгәнчә атлап яки юртып баруына буйсынып, Шантильи белән Кревкер арасындагы алты-җиде лье чамасы юлны әнә шулай ярым төш күргән сыман бер хәлдә узды һәм бу авылга килеп җитү белән үк юлда очраган нәрсәләрнең барысын да онытты.

Шушы авылга житкәч кенә егет уйларыннан айнып киткән кебек булды, башын селкеп куйды, теге чакта Арамисны калдырып киткән мәйханәне күреп алды һәм атын юрттырып китеп, ишек төбенә барып туктады.

Бу юлы аны хуҗа үзе түгел, аның хатыны каршы алды. Д'Артаньян кешенең күңеле турында аның чыраена карап фикер йөртүчеләрдән иде; ул трактирчы хатынның бик канәгать чырайлы симез йөзенә күз төшереп алды да хәйләгә салышып маташырга кирәк булмас дигән фикергә килде: мондый ачык чырайлы хатынның эчендә яманлык ятмас дип уйлады.

— Хөрмәтле хуҗа ханым,— дип эндәште аңа д'Артаньян,— моннан атна-ун көн чамасы элек бирегә мин бер дустымны калдырып киткән идем, сез шуның хәзер кайда икәнлеген әйтә алмассызмы?

— Егерме өч-егерме дүрт яшьләрендәге чибәр генә егетме — ягымлы сүзле, сабыр гына холыклы, төз генә буйлы?

— Өстәвенә, кулбашы да яраланганмы?

— Әйе, әйе.

— Димәк?

— Монда әле ул, әфәндем!

— Менә монысын ук көтмәгән идем! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян һәм атыннан төшеп, тезгенне Планше-

га ташлады.— Хужа ханым, сез бит миңа җан өрдегез! Кайда соң ул минем газиз Арамисым? Минем аны кочаклап бер үбәсем килә. Ихластыр, аны күрми түзәрлек хәлләрем калмады.

— Гафу итегез, әфәндем, ул сезне хәзер үк кабул итә алыр микән соң?

— Нигә? Әллә янында берәр хатын-кыз заты бармы?

— И аллам! Ни сөйлисез! Бичара егеткәй! Юк, әфәндем, аның янында хатын-кыз түгел.

— Кем соң?

— Мондидьедан килгән изге ата белән Амьендагы иезуитлар монастыренын назире.

— Ай аллам! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян.— Әллә бичараның хәле начарланып киттеме?

— Юк, әфәндем, киресенчә әле. Авыруыннан савыккач, ходайның теләге иңеп, рухани булырга ният кылган ул.

— Ә, әйе шул, онытып җибәргәнмен: аның мушкетер булып йөрүе вакытлыча гына бит,— диде д'Артаньян.

— Соң, әфәндем, сезнең аны бик тә күрәсегез киләме?

— Бик тә күрәсем килә шул!

— Ул чагында баскычтан менегез дә — ишегалдында уң кулда — өченче кат, бишенче номер булыр.

Д'Артаньян әйтелгән якка таба тиз генә китеп, баскычны тапты — ара-тирә иске мәйханәләрдә очраштыра торган тышкы бер баскыч иде ул. Мәгәр булачак аббат янына керүе алай бик ансат булмады: Арамис бүлмәсе ишеге төбендәге сак Армида бакчаларындагыдан бер дә ким түгел иде. Коридорда сакта торган Базен гайрәтләнеп д'Артаньянның юлына аркылы төште, чөнки, ничәмә еллар интегеп яшәгәннән соң, ул бичара үзенең көткән максатына якынлаша башлаган иде.

Чыннан да, Базен бик күптәннән инде рухани кешенең хезмәтчесе булырга хыяллана һәм Арамисның өстеннән мушкетер плащын салып рухани җиләне кигәнен түземсезлек белән көтә иде. Тик мушкетер егетнең көн саен, күп көтәсе калмады инде, дип юатуы, өметләндерүе генә аны Арамиста хезмәтчелектә тотып тора, чөнки, Базенның әйтүенчә, мушкетер хезмәтчесе булу — ул тәгаен газиз башкаеңны харап итү дигән сүз иде.

Шулай итеп, Базенның хәзер күңеле татлы хыял белән тулган чагы иде. Хәлбуки, бу юлы инде хуҗа әфәндесе үзенең әйткән сүзеннән ваз кичәргә тиеш түгел. Тән ярасы белән җан ярасы икесе бергә кушылып, күптән көткән тәэсирен ясады; бер үк вакытта тән газабы да һәм җан газабы да кичергән Арамис ниһаять күңелен дингә баглады, үз башына төшкән ике бәхетсезлекне — сөяркәсенең кинәт юкка чыгуын һәм кулбашы яралануын — ходайның искәртеп куюы дип санады, күрәсең.

Билгеле инде, кәефе шундый хозур чагында Базен өчен д'Артаньянның килеп чыгуыннан да яманрак хәлнең булуы

мөмкин түгел иде, чөнки аның килүе Базенның хуҗасын ничәмә еллар буе мавыктырган фани дөнья мәнфәгатьләре чоңгылына яңадан алып кереп китүе ихтимал иде. Шуңа күрә ул бүлмә ишегенкаһарманнарча сакларга карар итте. Трактирчы хатыны инде Арамисның бирeдә икәнлеген әйтеп ташлаган иде, шуңа күрә Базен, Арамис өйдә юк, дип әйтә алмаганлыктан, килгән кунакка: хуҗам савап кылган чагында аңа комачау итү бик зур ихтирамсызлык булыр иде, дип аңлатырга тырышып карады. Базенның әйтүенә караганда, Арамисның саваплы әңгәмәсе инде иртүк башланган булган һәм әле кичсез дә бетәсе түгел икән.

Мәгәр д'Артаньян метр Базенның тәфсилләп аңлатуына игътибар да итмәде. Дустының хезмәтчесе белән бәхәскә керергә җыенмастан, бер кулы белән аны читкәрәк этеп кенә җибәрде дә икенче кулы белән 5 ле саны язылган ишекнең тоткасын борды.

Һәм, ишек ачылу белән, д'Артаньян бүлмәгә кереп тә китте.

Арамисның өстендә иркен кара җилән, башында — скуфьяга тартым түгәрәк яссы калфак булып, ул кәгазь төргәкләре һәм зур-зур фолиантлар өелгән озын өстәл янында утыра, аның уң ягына иезуитлар монастыре назире, сул ягына Мондидьедан килгән изге ата утырган. Тәрәзә пәрдәләре яртылаш корылган булып, ачык калган өлешеннән күңелне дини уйларга оета торган серле бер яктылык саркып керә. Яшь кешенең, бигрәк тә мушкетер егетнең бүлмәсендәге күзгә ташланырдай фани дөнья әйберләре әфсен укып өргәндәй юкка чыккан; Базен, күз алдында торган ул әйберләр хуҗа әфәндесенең күңелен фани дөньяга кире кайтармагае дип куркып күрәсең, кылыч, пистолетларны, каурыйлы эшләпәне, һәртөрле челтәр һәм чигүле бизәкләрне ераграк җыештырып куйган.

Шуларның барчасы урынына карангы почмакта стенадагы кадакка ниндидер әйбер элеп куелган, ул әйбер д'Артаньянга тән җәзасы өчен кулланыла торган камчы сыман бер нәрсә булып күренде.

Ишек ачылган тавышка Арамис башын күтәреп карады, дустын шундук танып алды, әмма, д'Артаньянның гаҗәбенә каршы, аның килеп керүе мушкетерга әллә ни тәэсир итмәде шикелле — Арамисның уйлары бу фани дөньядан шактый ерак йөри иде булса кирәк.

— Хәерле көн, д'Артаньян дус, сезне күрүемә бик шатмын,— дип кенә куйды Арамис.

— Мин дә шатмын, гәрчә Арамис белән сөйләшүемә ышанып җитмәсәм дә,— диде д'Артаньян.

— Нәкъ үзе белән сөйләшәсез, дустым, нәкъ үзе белән! Нидән алай андый шик туды соң әле?

— Әллә бүлмәне ялгыштырдыммы дип курка калдым, берәр диндар кеше бүлмәсенә килеп кердемме дип уйлаган идем, аннары, сезне бу изге аталар янында күргәч, тагын бер ялгыш

уйга килдем: сез бик каты авыруга дучар булгансыз кебек күренде.

Кара киемле кешеләр икесе дә, д'Артаньянның кинаясен аңлап, егеткә усал гына итеп күз ташлап алдылар, ләкин д'Артаньянның моңа бер дә исе китмәде.

— Бәлки, мин сезгә комачаулыймдыр, Арамис дус? — диде д'Артаньян.— Күрүемчә, бу изге аталар алдында сез тәүбә итәсез шикелле.

Арамис бераз кызарыбрак китте.

— Миңа комачаулыйм дисезме? Юк, дустым, киресенчә, ант әгәр, шулай. Сүземнең чынлыгын раслап, сезне сау-сәламәт күрүемә бик шатланганымны белдерергә рөхсәт итегез.

«Ниһаять, аңлады! Ярый әле, яманрак булуы да ихтимал иде»,— дип уйлап куйды д'Артаньян.

— Чөнки минем дустым әле күптән түгел генә бик зур бер хәвефтән котылды,— дип күңеле хушланып сөйләвендә дәвам итте Арамис, ике руханига д'Артаньянны күрсәтте.

— Ул чагында аллага шөкранә кылыгыз, әфәндем,— диделәр тегеләр икесе берьюлы баш иеп.

— Кылдым инде, кылдым, изге аталар,— дип җавап кайтарды егет, шулай ук баш иеп.

— Бик вакытлы килдегез әле, д'Артаньян дус,— диде Арамис,— сез дә, безнең моназарага катнашып, белгәннәрегез белән ярдәм итәрсез безгә. Менә без өчәү — Амьен монастыре назире хәзрәтләре, Мондидьедан килгән кюре хәзрәтләре һәм мин — күптән игътибарыбызны җәлеп итеп килгән кайбер дини мәсьәләләрне тикшерәбез. Сезнең фикерегезне дә белсәм, мин бик шат булыр идем.

Д'Артаньян әңгәмәнең кирәкмәгән якка кереп китә башлавына беркадәр борчылып:

— Гаскәри кеше фикеренең әһәмияте юк; ихластыр, сез бу изге аталарның белеменә бик ышанып эш итә аласыз,— диде.

Кара киемле ике кеше тагын башларын иеп алдылар.

— Киресенчә, сезнең фикерегез безнең өчен бик кыйммәт булачак,— диде Арамис.— Сүз менә ни хакында: монастырь назире хәзрәтләре әйтә: минем диссертация күбесенчә догматик һәм дидактик булырга тиеш, ди.

— Сезнең диссертация! Диссертация язасызмыни сез?

— Әлбәттә,— диде иезуит,— рухани дигән изге дәрәҗә алганчы сыналу өчен диссертация язу лазем.

— Изге дәрәҗә алганчы! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян. Ул башта трактирчы хатынны, аннары Базен әйткәнгә ышанмаган иде.— Изге дәрәҗә алганчы!

Һәм д'Артаньян, шаккатып, каршындагы кешеләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күз йөртте.

Арамис берәр бай ханымның йокы бүлмәсендә иртәнге күрешүдәге кебек, креслосында бик нәфис бер позага кереп һәм хатын-кыз беләге төсле ап-ак симез беләгенә сокланып карый-

карый (кулын, кан саумасын дип, өскә күтәргән иде), ул сүзендә дәвам итте:

— Шулай итеп, д'Артаньян, ишеткәнегезчә, монастырь назире хәзрәтләре минем диссертациямнең догматик булуын тели, мин исә аның үземчә тәфсирләбрәк язылган булуын кулай күрәм. Әнә шул сәбәпле монастырь назире хәзрәтләре әле беркем тарафыннан да каралмаган, «Utraque manus in benedicendo clericis inferioribus necessaria est» дигән тема тәкъдим итте. Бу тема фикер йөртү өчен киң мәйдан ача, ди. Анысын мин дә икърар итәм.

Безгә д'Артаньянның латин телен белү чамасы билгеле иде инде, шуңа күрә ул әлеге цитатаны, де Тревиль әфәнденең бүләкләр хакында әйткәнен тыңлагандагы кебек, гамьсез бер төс белән тыңлап торды.

— Моның мәгънәсе шул була,— диде Арамис, дустының хәлен җиңеләйтергә тырышып: — «Кече дәрәҗәдәге руханиларга фатиха бирү өчен ике кул кирәк».

— Бик шәп тема! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды иезуит.

— Бик шәп вә догматик тема! — дип җөпләде изге ата. Аның да латин телен белүе д'Артаньянныкы чамасындарак иде, шуңа күрә ул иезуит артыннан ияреп, аның сүзләрен җөпләп бару өчен, иезуитны бик игътибар белән күзәтеп утыра иде.

Д'Артаньянга килгәндә исә, кара киемле бу ике кешенең аһ итүенә аның кылы да селкенмәде.

— Әйе, бик шәп! Prorsus andmirabile *,— диде Арамис,— әмма ләкин чиркәү аталарын һәм изге китапны тирәнтен өйрәнүне сорый. Хәлбуки,— галим руханилар алдында икърар итеп әйтәм — төнге каравылда кизүлек итү вә корольгә хезмәт итү дин сабагына беркадәр зыян китерде. Шуңа күрә теманы үзем сайласам, миңа җиңелрәк, facilius natans ** булыр иде. Метафизика белән фәлсәфә өчен әхлак мәсьәләсе нинди булса, бу кыен мәсьәләләр өчен дә дини тәгълимат шундый булыр иде.

Д'Артаньянга коточкыч күңелсез иде, кюреның да эче поша башлаган иде.

— Уйлап кына карагыз, нинди кереш! — дип кычкыра салды иезуит.

Нәрсә булса да әйтү өчен генә кюре да:

— Exordium ***,— дип җөпләп куйды.

— Quemadmodum inter coclorum immensitatem ****.

Шул вакыт Арамис д'Артаньян ягына күз салды — дусты казна сөякләре каерылыр дәрәҗәдә авызын ачып иснәнеп тора иде.

---

* Просто шәп (*латинча*).
** йөзүчегә җиңелрәк (*латинча*).
*** Кереш (*латинча*).
**** иксез-чиксез күктәге кебек (*латинча*).

— Әйдәгез французча гына сөйләшик, изге ата,— диде Арамис иезуитка,— шуннан соң д'Артаньян әфәнде дә безнең әңгәмәне яхшырак төшенер.

Д'Артаньян да:

— Әйе шул, мин юл килеп шактый арыганмын, латин сүзләре аңыма кереп җитми,— диде.

— Яхшы,— диде иезуит, үзен беркадәр сүз тәртибеннән чыгаруларына кәефе китеп; кюре исә, бик шатланып, д'Артаньянга рәхмәтле бер күз белән карап алды.— Алайса, карап карыйк: бу глоссадан нәрсә чыгарып булыр икән. Моисей, ходайның хезмәтчесе... ул фәкать ходайның хезмәтчесе генә, белегез! Моисей фатиха биргәндә ике кулын да күтәрә. Яһүдиләр дошманнарын җиңгәндә ул үзенең ике кулын да күтәргән килеш тотып торырга куша, димәк, ул фатиха биргәндә ике кулын да күтәрә. Янә инҗилдә дә әйтелгән: «Imponite manus» диелгән, «manum» диелмәгән. «Кулыгызны» түгел, «кулларыгызны куегыз».

Кюре да тиешле жест ясап:

— Кулларыгызны куегыз,— дип җөпләде.

— Ә изге Петрга,— папалар аның ярдәмчеләре генә,— дип сүзендә дәвам итте иезуит,— киресенчә әйтелгән: «Porrige digitos» — «Бармакларыгызны сузыгыз» диелгән. Аңладыгызмы инде?

— Әлбәттә, аңладык, әмма мәгънәсе бик нечкә,— диде Арамис, әңгәмәнең ләззәтенә бирелеп.

— Бармаклар! — дип кабатлады иезуит.— Изге Петр бармакларын сузып фатиха бирә. Шулай булгач, папа да бармакларын сузып фатиха бирә дигән сүз. Ничә бармагы белән фатиха бирә? Өч бармагы белән: Ата, Угыл һәм Изге рух хакына.

Шулай дигәч, барысы да чукынып алдылар; алардан күреп, д'Артаньян да төртенеп алды.

— Папа, Изге Петрның урынбасары булып, үзенә өч илаһи сәләхият туплаган; калганнары, рухани иерархиянең ordines inferiores *лары, өлкән фәрештәләр һәм фәрештәләр исеме белән фатиха кылалар. Иң кечкенә руханилар исә, әйтик, безнең дьяконнар һәм ризничийлар, фатиха бирә торган бик күп бармак сурәтендәге изге су бөркәгеч белән фатиха кылалар. Гадиләштергән сурәттә тема шундый, Argumetum omni denudatum ornamento **. Мин аннан моның ише ике тема ясар идем,— дип өстәп куйды иезуит.

Ул, бик дәртләнеп китеп, авырлыгы белән өстәлне сыгып торган изге Иоанн Оста китабына учы белән шап иттереп сугып та алды.

Д'Артаньян сискәнеп китте.

---

* түбән чиннары.
** Бернинди бизәүсез исбат.

— Әлбәттә, мин андый теманың күркәмлеген таныйм,— дип сүзгә керешә Арамис,— шул ук вакытта үземнең көчем җитмәслеген дә икърар итәргә тиешмен. Мин икенче текст сайладым. Әйтегез әле, д'Артаньян дус, сезгә ошадымы ул: «Non inutile est desiderium in oblatione» ягъни: «Ходай хакына корбан биргән кешегә беркадәр үкенү дә ярый».

— Туктагыз! — дип кычкыра салды иезуит.— Туктагыз, бу көфер сүз. Ересиарх Янсенийның «Augustinus» дигән китабында да шундый ук хәл диярлек. Ул китап иртәме-соңмы палач кулы белән утта яндырылачак. Сак булыгыз, егетем, сезнең ялган тәгълиматка таба тайпылып китүегез ихтимал. Үзегезне үзегез харап итәчәксез, егетем!

Кюре да кайгыга төшкән бер төс белән башын чайкап:

— Үзегезне үзегез харап итәчәксез,— дип җөпләде.

— Сез ихтыяри ирек дигән яман бер мәсьәләгә кагылдыгыз. Адәм баласын харап итә торган васвәсә ул. Сез пелагианлылар белән ярым пелагианлыларның ялган тәгълиматына барып чыктыгыз.

Арамис, үзенә каршы таш урынына яуган дәлилләрдән беркадәр аптырашта калып:

— Шулай да, изге ата...— дип сүз әйтмәкче булган иде дә, иезуит аны бүлдереп:

— Үзеңне ходай хакына корбан иткән чагында фани дөньяны сагыну кирәклеген ничек исбат итәрсез соң сез? — диде.— Менә мондый дилемманы тыңлагыз: ходай — илаһи, изге, ә фани дөнья — иблис. Димәк ки, фани дөньяны сагыну иблисне сагыну була; минем фикерем менә шулай.

— Минеке дә шулай,— дип куйды кюре.

Арамис тагын:

— Сабыр итегез әле!..— дип сүзгә башлаган иде, иезуит:

— Desideras diabolum *, бичара бәндә! — дип кычкырды.

— Иблисне сагына ул! Ай, егетем, иблисне сагынмагыз, гозерләп әйтәм,— дип аһ-үһ килде кюре.

Д'Артаньян үзен миңгерәүләнеп калгандай тойды; ул үзен юләрләр йортына килеп кергән кебек хис кылды, каршында утырган кешеләр шикелле, менә хәзер үзе дә акылыннан язар кебек тойды. Шулай да егет дәшми генә тик торырга мәҗбүр булды, чөнки тегеләр әңгәмә кылган телне белми-төшенми иде ул.

Арамис инде беркадәр үртәлә башласа да, әдәпле генә итеп:

— Шулай да сүземне тыңлагыз әле,— диде.— Мин бит сагынам дип әйтмим. Юк, мин ул сүзне беркайчан да әйтмәячәкмен, чөнки ул хак диннең рухына туры килми...

Иезуит кулларын күккә таба сузды, кюре да нәкъ шулай итте.

---

* Иблисне сагынасын.

— Үзегез тәмам туеп, гарык булган нәрсәне ходайга корбан итү килешми — шулай бит инде?! Д'Артаньян, әйтегез әле: мин хаклы түгелмени?

— Әлбәттә, хаклы, шайтан алгыры! — дип кычкыра төшеп әйтте д' Артаньян.

Кюре белән иезуит утырган урыннарында дерт итеп сикерешеп куйдылар.

— Менә минем төп нигез ноктам, мондый силлогизм: фани дөньяда рәхәтлекләр юк түгел: мин бу дөньядан китәм, димәк, корбан бирәм; изге китапта да туп-туры әйтелгән бит: «ходайга корбан бирәм» диелгән.

— Анысы дөрес,— диделәр каршы фикердәгеләр.

— Аннан ары,— диде Арамис, колагын чеметкәләп. Башта ул беләгем агара төшсен дип кулын өскә күтәргән иде, хәзер исә колагым кызарсын дип колак яфрагын чеметкәли башлаган иде,— аннан ары мин бу темага рондо да язган идем; мин аны былтыр Буатюр әфәндегә дә күрсәткән идем, шул бөек кеше бик күп мактау сүзләре әйткән иде миңа.

— Рондо! — дип мыскыллы бер төс белән әйтеп куйды иезуит.

Аңа ияреп кюре да:

— Рондо! — диде.

— Безгә укыгыз әле шуны, укыгыз әле! — диде д'Артаньян кычкыра төшеп.— Бераз күңеллерәк булып китәр ичмасам.

— Юк, дини эчтәлекле нәрсә бит ул, шигырь итеп язылган догалык,— диде Арамис.

— Ниткән әкәмәт ул тагын?! — дип куйды д'Артаньян.

— Болай ул,— диде Арамис юаш кына, сабыр гына бер кыяфәттә, әмма беркадәр риялану да юк түгел иде үзендә.

«Бәхетсез дип ут йотасың нигә,
Өметсез мескенгә сабыштың?
Күз яшьләрең бирсәң бер тәңрегә,
Котылырсың кайгы-сагыштан.
Бәхетсез дип...»

Д'Артаньян белән кюрега шигырь бик ошады. Иезуит исә үз фикереннән чигенмәде.

— Дини сүзгә фани дөнья рухы кертүдән сак булыгыз. Изге Августин нәрсә ди? Severes sit clerocorum sermo *, ди.

— Әйе, вәгазь аңлаешлы булырга тиеш! — дип куйды кюре.

Иезуит, нәрчененең ялгышып китүен күреп, тизрәк сүзгә кушылды:

— Шулай итеп, сезнең диссертациягез бары тик дамаларга гына ошаячак; Патрю әфәнденең берәр нәрсәне яклап сөйләгән нотыгы шикелле уңыш казаначак.

— Бирсен ходай! — дип дәртләнеп әйтеп куйды Арамис.

---

* Клирикларның сүзе кырыс булсын.

— Менә күрәсезме! — диде иезуит.— Фани дөнья сезнең күңелегездә нык утыра әле, altissima voce * аваз бирә. Сез әле, егетем, бу дөнья кешесе, шуңа күрә сезнең өчен куркамын мин; ходайдан теләгәнегезнең кабул булмавы ихтимал.

— Борчылмагыз, изге ата, үзем өчен мин үзем җавап бирәм.

— Фанилар үҗәтлеге.

— Үземне үзем беләм мин, изге ата, карарымнан кире чикмим.

— Димәк, сез бу тема өстендә эшләвегезне дәвам иттермәкче буласыз?

— Мин үземне нәкъ шушы теманы тикшерергә тиешлемен дип хис кылам. Шул сәбәпле бу эшемне дәвам иттерәчәкмен. Сезнең күрсәтмәләргә таянып, төзәтмәләр керткәннән соң, сез иртәгә үк ул төзәтмәләрдән канәгать булырсыз дип өметләнәм.

— Ашыкмый гына эшләгез, без сезне бик әйбәт халәте рухиядә калдырып китәбез,— диде кюре.

— Әйе,— диде иезуит та,— орлыклар үз туфрагына төшкән, орлыкның бер өлеше таш өстенә эләккән яки юлда чәчелеп калган, я булмаса бер өлешен ходайның сайрар кошлары чүпләр дип куркасыбыз юк, aves coeli comederunt illam.

Д'Артаньян, үзенең тәмам түнә башлаганын тоеп:

«Латиның белән бергә тизрәк олаксаң икән моннан»,— дип сөйләнеп куйды күңеленнән.

— Сау булыгыз, улым, иртәгә күрешкәнче,— диде кюре.

— Сау булыгыз, батыр егет,— диде иезуит,— сез чиркәүнең якты шәме булырсыз дигән өмет уятасыз. Тик, ходай кушып, ул шәм комсыз бер ялкынга гына әйләнмәсен инде!

Д'Артаньян түземсезлектән сәгать буе тырнакларын кимергәләп утырган иде, хәзер инде бармакларын ук тешләштерергә керешге.

Кара җиләнле ике кеше, урыннарыннан торып, Арамис белән д'Артаньянга баш иеп саубуллаштылар да ишеккә таба юнәлделәр. Әлеге гыйльми моназараны диндарларча мөкиббән китеп, сокланып башыннан азагына хәтле тыңлап торган Базен аларның каршысына йөгереп килде дә изге атаның догалыгын, иезуитның гыйбадәт китабын алды һәм, аларга хөрмәт күрсәтеп, алдан юл сабып китте.

Арамис, аларны озата чыгып, бергәләп баскычтан төште дә шундук д'Артаньян янына әйләнеп тә менде. Д'Артаньян әле һаман да ялыгуыннан айнып җитмәгән шикелле иде.

Бүлмәдә икәү генә калгач, дуслар уңайсыз бер хәлдә беркадәр сүзсез тордылар; тик кайсынадыр барыбер беренче булып сүз башларга кирәк булачак иде, шуңа күрә, д'Артаньян бу эшне дустына тапшырырга карар итте булса кирәк,— беренче булып Арамис сөйләшә башлады.

---

* иң каты тавышы белән.

— Күрәсез, мин үземнең изге уйларыма әйләнеп кайттым,— диде ул.

— Әйе, әле генә изге ата әйтмешли, ходайдан теләгәнегез кабул булган.

— О, бу фани дөньядан читләшү нияте минем күңелемдә күптән туган иде инде, ул хакта миннән бер генә тапкыр ишетмәгәнсездер, шулаймы, дустым?

— Ишеткәнем бар иде дә, тик мин сезне шаяртасыз дип кенә уйлаган идем.

— Андый нәрсә белән шаярталармыни? Ни сөйлисез, д'Артаньян!

— Шайтан алгыры! Әҗәл белән дә шаярабыз бит әле.

— Анысы юкка, д'Артаньян, чөнки әҗәл — я һәлакәткә, я котылуга илтә торган капу ул.

— Килешәм, тик, Арамис, алла хакы өчен, дини бәхәсләрне куеп торыйк әле. Минемчә, булган кадәресе дә бүгенгә бик җиткән сезгә. Миңа килгәндә исә мин латинны барлы-юклы белгәнемне дә онытып бетерә язганмын инде, аннары, ихластыр, иртәнге уннан бирле авызыма валчык та ризык капканым юк, бүре кебек ач мин.

— Хәзер ашарбыз, дустым, тик шуны онытмагыз: бүген җомга көн, андый көннәрне мин итне ашау түгел, аңа карый да алмыйм. Әгәр сез мин ашый торган ризыкка риза булсагыз, ул пешкән тетрагон белән җимешләрдән гыйбарәт.

— Тетрагон дигәнегез ни була соң инде? — дип борчылып сорады д'Артаньян.

— Шпинат була,— диде Арамис,— сезнең өчен ул ашка күкәйләр дә өстәрмен, монысы инде кагыйдәне шактый бозу була, чөнки күкәйдән чеби туа, димәк, ул ит була.

— Әллә ни искитәрлек сый түгел түгелен дә, сезнең белән мәҗлестәш булу хөрмәтенә генә риза булам инде.

— Андый корбан бирүегез өчен рәхмәт,— диде Арамис,— тәнегезгә әллә ни сихәте булмаса да, җаныгыз өчен, шиксез, файдасы булмый калмас.

— Димәк, сез, Арамис, руханилыкка китәргә карар кылдыгыз? Дуслар ни дияр икән соң, де Тревиль әфәнде нәрсә дияр? Әйтеп куям: алар сезне дезертир дип санаячак.

— Руханилыкка китмим мин, руханилыгыма кире генә кайтам. Дезертир булсам да, мин фани дөнья өчен ташлап киткән чиркәүгә карата гына дезертирмын. Өстемә мушкетер киемен үземне-үзем көчләп кигәнемне беләсез бит.

— Юк, мин ул хакта берни белмим.

— Минем ни сәбәпле семинарияне ташлаганым сезгә мәгълүм түгелмени?

— Түгел.

— Минем баштан кичкән хәлләр шундый. Хәтта иң изге китапта да әйтелгән: «Бер-берегезгә эч серләрегезне чишегез», диелгән. Менә мин сезгә чишәм инде, д'Артаньян.

— Ә мин гөнаһларыгызны алдан ук кичереп куям,— күрдегезме: нинди мәрхәмәтле кеше мин.

— Изге нәрсәләр белән шаярмагыз, дустым.

— Я, я, сөйләгез, тыңлыйм.

— Мин тугыз яшемнән алып семинариядә тәрбияләндем. Тагын өч көннән соң инде миңа егерме тулып, мин аббат була идем дә шуның белән эш тә бетә иде. Беркөнне шулай гадәтемчә бер йортка кич утырырга баргач,— нишлисең бит: яшь чак, җүләр чак! — минем хуҗа хатынга изгеләр китабын укыганымны гел көнләшеп күзәтеп йөргән бер офицер искәрмәстән, әйтми-нитми бүлмәгә килеп керде. Нәкъ шул кичне мин Юдифь тарихыннан бер эпизод тәрҗемә иткән идем, һәм әле яңа гына дамама шигырь укып күрсәткән идем. Хуҗа ханым шигырьне бик мактады, башын җилкәмә салып, минем белән бергә шул шигырьне кабат укый тора иде. Шушы торыш, дөресен әйткәндә, беркадәр тыйнаксызрак тотыш, офицерга ошап бетмәде; башта ул берни әйтмәде, инде мин кайтып китәргә җыенгач, артымнан нярен чыкты.

«Аббат әфәнде, үзегезне таяк белән кыйнасалар, шул ошар идеме сезгә?» — ди бу, артымнан җитеп.

«Бу соравыгызга җавап бирә алмыйм, әфәндем, чөнки моңарчы берәүнең дә әле мине кыйнарга батырчылык иткәне юк»,— дидем мин.

«Алайса, белеп торыгыз, аббат әфәнде, әгәр дә мәгәр менә бүген без очрашкан шушы йортка тагын бер тапкыр килсәгез, мин сезне кыйнарга батырчылык итәчәкмен»,— ди бу.

Мин шүрли калдым шикелле. Йөзем агарынып китте, тез буыннарым калтырый башлады, каршы әйтергә сүз эзләп карадым — таба алмадым, эндәшмәдем.

Офицер минем җавап кайтарганымны көтеп торды да, эндәшмәгәнемне күргәч, шаркылдап көлеп җибәрде, аннары миңа арты белән борылды да йортка кереп китте. Мин семинариягә кайтып киттем.

Мин бит инде чын дворян, д'Артаньян дус, белгәнегезчә, кайнар канлы кешемен; минем өчен коточкыч бер хурлык булды бу, моны беркем белмәсә дә, шул нәрсә минем бәгыремә төшеп, яндырып тора башлады. Шуннан соң мин изге аталарга әйттем: рухани булырга минем әле әзерлегем җитәрлек түгел, дидем, һәм минем үтенечем буенча рухани итү йоласын тагын бер елга кичектерделәр.

Мин Парижга, кылыч белән сугышырга өйрәтүче иң яхшы бер оста янына барып, көн саен аңардан дәрес алырга сөйләштем, шулай итеп ел буе аңардан көн саен дәрес алдым. Аннары, теге чакта мыскыл ителүемә бер ел тулган көнне, җиләнемне чөйгә элеп, дворяннарча киендем дә бер таныш ханым җыйган балга киттем. Әлеге дошманым да шунда булырга тиеш иде. Форс тәрмәсеннән ерак түгел, Фран-Буржуа урамында иде ул йорт.

Теге офицер чыннан да шунда булып чыкты; мин аның бер хатынга назлы күзләре белән карап гыйшык җыры җырлап торган чагында гына янына килдем дә икенче куплетының урта бер җирендә җырыннан бүлдереп:

«Әфәндем, әйтегез әле: әгәр дә мин сезгә мәгълүм булган Пайен урамындагы теге йортка кабат барсам, сез һаман да каршы төшәрсезме? Сезнең сүзгә колак салмасам, мине таяк белән кыйнарсызмы?» — дидем.

Офицер бик сәерсенеп миңа карады да:

«Әфәндем, ни кирәк сезгә миннән? Мин сезне бөтенләй белмим»,— диде.

«Мин теге, изгеләр китабын укучы, «Юдифь»не шигырь белән тәрҗемә итүче яшь аббат булам»,— дидем мин моңа.

«Әйе, әйе. Хәтерлим! Ни кирәк соң сезгә?» — ди бу мыскыллы гына елмаеп.

«Миңа сезнең минем белән урамга чыгып йөрүегез кирәк»,— мин әйтәм.

«Бик теләсәгез, иртәгә иртән йөрербез, өстәвенә, бик риза булып»,— ди бу.

«Юк,— мин әйтәм,— иртәгә иртән түгел, хәзер үк чыгыйк»,— дим.

«Алай бик таләп итәсез икән...» — ди бу.

«Әйе, таләп итәм»,— мин әйтәм.

«Алайса, әйдәгез киттек,— ди.— Ханым әфәнделәр, бер дә борчылмагыз. Мин бу әфәндене үтерәм дә, кире кайтып, соңгы куплетны җырлап бетерермен»,— ди бу дамаларга.

Шуннан чыгып киттек.

Мин аны Пайен урамына, моннан бер ел элек теге чакта миңа әлеге комплиментны әйткән төшкә алып бардым. Бик матур айлы бер кич иде. Кылычларыбызны кыныларыннан суырып чыгардык та мин аны бер селтәнү белән үк кадап та үтердем.

— Ах, шайтан алгыры! — дип куйды д'Артаньян.

— Теге дамалар янына җырчылары әйләнеп кайтмагач, аннары теге, кылыч белән кадап үтерелгән килеш, Пайен урамыннан табылгач, моны минем эш икән дип белделәр, бу хәл бик зур шау-шу кузгатты,— дип сөйләвендә дәвам итте Арамис.— Шуның нәтиҗәсендә мин беркадәр вакыт рухани җиләнен салып торырга мәҗбүр булдым. Атос белән Портос (Атос белән мин нәкъ шул вакытларда танышкан идем, ә Портос, теге фехтование дәресләренә өстәп, тагын кайбер шәп кенә алымнарга да өйрәткән иде) — шулар мине мушкетерлыкка керергә үгетләделәр. Минем эти Аррасны камаган чакта үлеп калган. Король аны бик ярата иде, шуннан инде мине мушкетер итеп алдылар. Үзегез дә аңлыйсыздыр, хәзер миңа нәкъ чиркәүгә сыгыныр вакыт җитте.

— Ә нигә ул хәзер, нигә элегрәк яки соңрак түгел? Сезгә ни булды соң, ни сәбәптән күңелегезгә шундый ямьсез уйлар килде?

— Д'Артаньян дус, бу ярам минем өчен ходайның бер кисәтүе, искәртеп куюы булды.

— Бу ярагыз? Һи, юкны сөйләмәгез! Төзәлеп килә бит инде ул. Минемчә, сезнең хәзер борчылуыгыз бу ярадан түгел.

— Нинди ярадан соң? — дип сорады Арамис кызарынып.

— Сездә йөрәк ярасы, Арамис. Хатын-кыз ясаган ул яра газаплырак һәм канлырак яра.

Арамисның ихтыярсыздан күзләре ялтырый башлады.

— Юк ла,— дигән булды ул, исе китмәгән бер төс белән дулкынлануын сиздермәскә тырышты,— андый нәрсәләр хакында сүз сөйләп тору кирәк микән? Мине мәхәббәт кайгысыннан ут йота дисезмени? Vanitas vanitatum! * Әллә сез мине акылын җуйган дип уйлыйсызмы — кем аркасында диегез? Гарнизонда чагымда йөргән берәр төрле гризетка яисә асрау кыз аркасында... Җирәнеп үләрсең!

— Гафу итегез, Арамис дус, мин сезне югарырактан чамалагансыздыр дип уйлаган идем.

— Һе, югарырактан! Алай сайланырга мин кем ул хәтле? Беркем күзенә чалынмый торган бичара бер ярлы мушкетер, кемгә дә булса бәйле булуны күрә алмый торган, дөньяда үзенең урынын таба алмаган бер кеше.

— Арамис, Арамис! — дип кычкыра төшеп эндәште д'Артаньян, дустына ышанмаган бер караш ташлап.

— Туфрактан яралганмын һәм туфрак булам. Яшәү ул кимлек-хурлык вә газап-михнәтләрдән гыйбарәт,— дип дәвам итте Арамис, караңгы бер чырай белән,— адәмне бәхеткә бәйләгән җепләр аның кулында бере арты бере өзелә бара, иң әүвәл алтын җепләр өзелә. Һай, д'Артаньян дустым,— диде Арамис, беркадәр офтанган тавыш белән,— тыңлагыз сүземне — яраларыгыз булса, кешегә сиздермәгез аларны. Сереңне эчеңдә генә саклау — мескен адәмнәрнең иң соңгы шатлыгы ул; ачы хәсрәтеңне беркемгә белгертмә. Чебеннәр яралы боланның канын эчкән кебек, кызыксынучы адәмнәр дә безнең күз яшебезне генә эчәләр.

— Әй, Арамис дус,— диде д'Артаньян да, үз нәүбәтендә авыр сулап,— сез бит миңа үз башымнан кичкәннәрне сөйлисез.

— Ничек алай?

— Шулай! Менә әле генә мин яраткан, өзелеп сөйгән хатынны урладылар. Мин аның кайда икәнен дә, кая алып киткәнлекләрен дә белмим: бәлки, ул төрмәдәдер, бәлки, дөньяда ук юктыр.

— Ичмасам, сезнең, бу бит мине үзе теләп ташламады, дигән юанычыгыз бар, аңардан хат-хәбәр булмавы аның сезнең белән бәйләнеш тота алмавыннан гына икәнен беләсез, ә минем...

* Фани дөнья мәшәкате генә бит ул.

— Сезнең нәрсә?..

— Бер нәрсә дә юк, бер нәрсә дә,— диде Арамис.

— Димәк, сез фани дөньядан бөтенләй ваз кичәсез, бу карарыгыз какшамаслык нык инде?

— Бөтенләй ваз кичтем. Бүген әле сез минем дустым, иртәгә инде сез минем өчен бер шәүлә генә булачаксыз яки минем өчен бөтенләй дөньяда юк булачаксыз. Дөнья ул нибары төрбә генә.

— Шайтан алгырысы! Шул хәтле дә күңелсез нәрсәләр сөйлисез!

— Нишләмәк кирәк соң инде! Тумыштан бирелгән омтылышым тарта, күкләргә аштыра мине.

Д'Артаньян җавап кайтармады, бары тик көлемсерәп кенә куйды.

— Мәгәр,— дип сүзендә дәвам итте Арамис,— әлегә фани дөньяда чагымда минем сезнең белән үзегез хакында, дуслар хакында сөйләшәсем килә.

— Минем дә сезнең белән үзегез хакында сөйләшәсем килә дә, сезнең күңелегез дөньялыктан бик ерак киткән шул,— диде д'Артаньян аның сүзенә каршы.— Сөю-сөелү сезгә җирәнгеч бер нәрсә булып тоела, дуслар сезнең өчен — шәүлә, дөнья да — төрбә генә...

— Шулай шул! Моңа үзегез дә ышанырсыз әле,— диде Арамис, көрсенеп.

— Ярый алайса, бу сүзне куеп торыйк. Әйдәгез хатны яндырыйк әле, ул хатта сезнең гризеткагыз яки асрау кызыгызның яңа бер хыянәте хакында әйтелгән булуы ихтимал.

— Нинди хат? — дип шундук кычкыра төшеп сорады Арамис.

— Сез югында сезнең исемгә бер хат килгән булган. Шуны сезгә тапшырырга кушканнар иде миңа.

— Кемнән ул?

— Белмим. Елый-елый шешенеп беткән берәр асрау кыздан, я булмаса, ут йотып ятучы гризеткадандыр, бәлки, де Шеврез ханымның асравыннандыр. Ул да үзенең бикәсе белән Турга кайтып китәргә тиеш булган. Үзенең бәясен арттырыр өчен хатын хушбуй сөрткән кәгазьгә язган да герцог таҗы төшерелгән печәт белән печәтләп ябыштырган.

— Нәрсә сөйлисез соң сез?

— Әллә югалтканмын инде хатны,— дигән булды егет, хатны эзләгән итенеп.— Ярый әле шунысы бәхет: дөнья ул — төрбә генә, адәмнәр, димәк ки, хатын-кыз да — шәүлә генә, ә мәхәббәт, сез әйтмешли, «җирәнеп үләрлек!» бер тойгы гына.

— Ай, д'Артаньян, д'Артаньян, үтерәсең бит син мине! — дип кычкырып җибәрде Арамис.

— Әһә, менә кайда икән! — дип, д'Артаньян кесәсеннән хат чыгарды.

Арамис, ялт кына торып, хатны тартып алды да шундук

укып, дөресрәге, күзләре белән сөзеп тә чыкты; йөзе балкып-нурланып китте.

— Асрау кызның теле бик нәфис-нәзакәтле булса кирәк,— дигән булды аманәтне тапшыручы.

— Рәхмәт, д'Артаньян! — дип кычкырып җибәрде Арамис шатлыгыннан шашкан кебек.— Турга кире кайтырга туры килгән икән аңа. Мине ташламаган ул, мине һаман сөя икән. Кил әле, дустым, кил әле, үзеңне бер кочыйм әле, шатлыкларым эчемә сыймый бит!

Һәм алар икәүләшеп, идәнгә чәчелгән диссертация битләрен рәхәтләнеп таптый-таптый, мөхтәрәм Иоанн Оста тирәли биергә керештеләр.

Шул минутта бүлмәгә, шпинат белән күкәй тәбәсе күтәреп, Базен килеп керде.

— Бар, йөгер, мәхлук! — дип кычкырды аңа Арамис, башлыгын Базенның йөзенә ыргытып җибәрде.— Бар, бу күңел кайтаргыч яшелчәләр белән җирәнгеч тәбәне кире илт. Шпиклаган куян ите, симез каплун, сарымсак белән кыздырган сарык ите һәм дүрт шешә иске бургунд шәрабы сора.

Базен хуҗасындагы бу үзгәрешне аңламыйча аптырап карап торганда күкәй тәбәсен шпинат өстенә, ә шпинатны паркетка төшереп җибәрде.

— Гомерегезне Патшалар Патшасына багышлар өчен бик җайлы вакыт инде,— диде д'Артаньян,— әгәр аның күңелен күрергә теләсәгез, дим: Non inutîle desîderîum in oblatîone.

— Чәнчелеп китсен лә шул латиныгыз! Әйдәгез эчәбез, д'Артаньян дус, эчәбез, шайтан алгыры, бик күп эчәбез. Әйдә сөйлә син миңа, андагы хәлләрнең барысын да сөйлә.

## *XXVII*

## *АТОСНЫҢ ХАТЫНЫ*

Табындагы яхшы, мул сый берсенең диссертациясен, икенчесенең арган-талганнарын оныттырды. Д'Артаньян дустына үзләре югында башкалада булган барлык яңалыкларны сөйләп чыкты. Шуннан соң кәефе күтәрелеп киткән Арамиска әйтеп куйды:

— Хәзер инде Атосның гына хәлен беләсе калды,— диде.

— Аңа бер-бер хәл булгандыр дисезме? Атос бит ул шундый сабыр, шундый батыр егет, кылыч белән дә шундый оста эш итә белә,— диде Арамис.

— Анысы, һичшиксез, шулай, Атосның батыр, чая булуын мин дә бик яхшы беләм, әмма, минемчә, кылыч белән таякка каршы торганчы сөңгегә каршы сугышу хәерлерәк. Атосны хезмәтчеләр кыйнап ташлаган булмагае дип куркам: нык сугыш

торган халык бит алар, сугышудан тиз генә туктамыйлар. Дөресен генә әйткәндә, әнә шуңа күрә минем тизрәк юлга чыгасым килә иде.

— Мин дә сезнең белән китәргә тырышып карыйм,— диде Арамис,— атка атланырлык чамам да юк шикелле. Кичә әнә теге стенадагы камчы белән үземә суккалап караган идем дә, авырта икән әле, андый савaплы эшне күп эшләп булмады.

— Пуля ярасын моңарчы берәү дә камчы белән дәвалаганы юк әле, дустым. Сез әлегә авыру кеше, ә авыру ул кешенең акыл сәләтен киметә, шуңа күрә бу эшегез өчен сезне гафу итәм.

— Кайчан китәсез?

— Иртәгә таң белән. Төнлә әйбәтләп йокыгызны туйдырырга тырышыгыз, иртәгә инде, хәл-чамагыз булса, бергәләп китәрбез.

— Алайса иртәнгә хәтле сау булып торыгыз,— диде Арамис,— тимер кебек таза булсагыз да, сезнең дә йоклыйсыгыз килә торгандыр.

Иртән д'Артаньян дусты янына килеп кергәндә, Арамис тәрәзә катында басып тора иде.

— Нәрсә карыйсыз анда? — дип сорады д'Артаньян.

— Әнә теге ат караучылар тотып торган бик шәп өч атка сокланып карап торам әле. Валлаһи, андый атларга атлану принцларга гына тәти торгандыр.

— Алай дип уйласагыз, Арамис дус, андый бәхет сезгә дә тәтер, чөнки шул атларның берсе сезнеке.

— Булмас ла! Кайсысы минеке?

— Сезгә кайсы күбрәк ошый — шунысы. Миңа нindие дә ярый.

— Өстендәге зиннәтле ияре дә минекеме?

— Әйе.

— Миннән көләсез сез, д'Артаньян.

— Сез французча сөйләшә башлаганнан бирле көлүдән туктадым инде мин.

— Алтынлаган кобурлар, бәрхет чапрак, көмеш белән чиккән ияр — шулар барысы да минекеме?

— Сезнеке, әнә теге тибенгәләп торган ат минеке, әнә тегесе, биеп торганы — Атосныкы.

— Ах, шайтан алгыры, өчесе дә искиткеч шәпләр бит!

— Сезгә ошауларына бик сөенәм.

— Аларны король бүләк иткәндер инде сезгә?

— Һәрхәлдә, кардинал түгел. Хәер, сез ул атларның каян килгәнлеге турында борчылмагыз, шунысын гына белегез: аларның берсе сезнеке.

— Мин әнә теге җирән хезмәтче тотып торганын алам.

— Бик яхшы!

— Валлаһи! — дип кычкырып куйды Арамис.— Бу атларны күргәч, бөтен авыртуым бетеп китте кебек. Мондый атка мин

тәнемдә утыз пуля булса да атланыр идем. О, өзәңгеләре генә дә нинди бит! Әй, Базен, килегез әле, тизрәк булыгыз!

Ишектән йокымсыраган күңелсез чырайлы Базен күренде.

— Минем кылычны ялтыратып куегыз, эшләпәне рәткә китерегез, плащны чистартыгыз һәм пистолетларны карап куегыз,— диде Арамис.

— Соңгысы артык,— диде д'Артаньян, аны сүзеннән бүлдереп,— андагы кобурларыгызда корган пистолетлар бар.

Базен авыр сулап куйды.

— Уфтанмагыз, метр Базен, тынычланыгыз, җәннәткә теләсә нинди кеше булсаң да керергә була бит,— диде д'Артаньян.

— Минем хуҗам бик яхшы дин белгече иде инде! — диде Базен еларга җитешеп.— Епископ була иде ул, бәлки, кардинал да булыр иде әле.

— Карале, Базен дус, яхшылабрак уйла да әйт әле — рухани булу нигә кирәк ул? Аңа карап кына бит сугыштан котыла алмыйсың. Менә үзең үк күрерсең: кардинал, башына шлем киеп, кулына айбалта тотып, беренче походка ук катнашачак. Ә Ногаре'де Лавалет әфәнде? Ул да кардинал бит, ә син аның лакееннан сора әле: ул аңа ничә тапкыр ярасын бәйләргә сүс йомшартып бирде икән?

— Шулаен шулай анысы! — диде Базен көрсенеп.— Беләм, әфәндем, бөтен дөньяның асты өскә килде хәзер.

Ике егет белән бичара лакей сөйләшә-сөйләшә аска төшеп киттеләр.

— Базен, өзәңгене тотып тор,— диде Арамис.

Ул гадәтенчә ияргә очып кына менеп атланды; әмма зат нәселле ат берничә тапкыр борылгалап, үрә баскалауга, җайдакның ярасы коточкыч авырта башлады, йөзе агарынып китте, гәүдәсе чайкалгалап алды. Д'Артаньян, моның шулай булырын чамалап, аңа караштыргалап торган иде — хәлне күрүгә, тиз генә дусты янына йөгереп килде дә аны, ат өстеннән төшереп, бүлмәсенә кертеп куйды.

— Менә нәрсә, Арамис дус, сез дәвалана торыгыз, мин Атосны үзем генә эзләп китәм,— диде.

— Сез бронзадан коелгансыздыр,— диде Арамис, дустының бу сүзенә каршы.

— Юк, минем бәхет бар, бары тик шул гына! Әйтегез әле: миннән соң ничегрәк яшәмәкче буласыз сез? Фатихалар, догалар турында бернинди сүз булмасмы, ә?

Арамис елмаеп куйды.

— Шигырьләр язармын,— диде.

— Әйе, әйе, шигырьләр язасыз, де Шеврез ханым асравының хаты шикелле, хушбуй сөрткән шигырьләр. Базенны да шигырь чыгарырга өйрәтегез, аңа да бераз юаныч булыр. Ат мәсьәләсенә килгәндә, көн саен аз-азлап йөреп керегез, сезгә ул яңадан иярга күнегергә ярдәм итәр.

— Һи, анысы өчен борчылмагыз, сез әйләнеп кайтуга мин инде сезгә иярергә әзер булып торырмын,— диде Арамис.

Шуннан соң алар саубуллашып аерылыштылар, д'Артаньян Базен белән хуҗа хатынга Арамисны әйбәтләп карарга әйтеп калдырды, һәм бер ун минуттан соң инде ул Амьен юлы буйлап атын чаптырып китеп бара иде.

Атосны нинди хәлдә эзләп табар икән ул һәм, гомумән, таба алыр микән аны?

Д'Артаньян Атосны бик хәтәр хәлдә калдырып киткән иде бит; аны үтергән булулары да ихтимал иде. Шул уй д'Артаньянның күңеленә борчу салды; ул берничә тапкыр көрсенгәләп куйды да аның өчен үч алырга ант итте.

Атос д'Артаньянның дуслары арасында иң өлкәне, шуңа күрә зәвыгы, теләк-омтылышлары белән иң ерагы булырга тиеш иде.

Мәгәр д'Артаньян башкаларга караганда аны яратарак төшә иде. Атосның чибәр, нәфис тәс-кыяфәте, гадәттә үзен күләгәдәрәк тотканда вакыт-вакыт олы җаны ачылып, яктырып китүе, кешене үзенә тарта торган сабыр холкы, усал шаянлыгы, батырлыгы (монысы аның гаҗәеп бер сабырлыгының нәтиҗәсе булмаса, сукыр батырлык дип тә әйтергә мөмкин иде),— аның әнә шул сыйфатлары д'Артаньянның күңелендә хөрмәт-ихтирам, дус итү генә түгел, бәлки соклану-таң калу хисе дә уята иде.

Чыннан да, хәтта төз буйлы, чибәр йөзле сарай кавалеры де Тревиль әфәнде белән янәшә торганда да Атос кәефле-дәртле чагында бер дә аңа бирешерлек түгел; үзе ул уртача гына буйлы, әмма гәүдәгә шундый төз һәм нык — Портос белән көрәшкәндә көчле-куәтле булуы мушкетерлар теленә әйтем булып кергән шул Алып батырны да җиңгәләгәне бар иде; аның йөзендә — үткен карашлы күзләрендә, туры борынында, Брутныкы төсле иягреңдә — ниндидер сизелер-сизелмәс кенә хакимлек һәм мөлаемлык әсәрләре дә бар, ә куллары, үзе аларга бернинди игътибар күрсәтмәсә дә, Арамисны бик чиктән көнләштерә, чөнки Арамисның үз куллары, гел бадам сабыннары белән генә юып, хуш исле майлар сөртеп кенә торса да, аныкы төсле матур түгел иде; Атосның тавышы да күкрәктән килә торган тирән һәм шул ук вакытта ягымлы, мөлаем бер тавыш иде... Әмма башкаларга күренмәскә, һәрвакыт кечкенә бер кеше булып калырга тырышучы Атосның тагын бер шаккаткыч сыйфаты бар — ул югары җәмгыять тормышының иң мәшһүр даирәнең гадәт-йолаларын бик яхшы белә, аның как-төяк эш-гамәлләрендә дә яхшы тәрбия эзләре чагыла иде.

Сүз аш мәҗлесе хакында барса, Атос андый мәҗлесне югары җәмгыять кешеләренең бөтенесеннән дә яхшырак итеп оештыра, һәр кунакны ата-бабалары яки үзе казанган дәрәҗәсенә бәрабәр тиешле урынына утырта. Сүз геральдика турында

булса, Атос король дәүләтендәге барлык дворян фамилияләрен, аларның нәсел тарихларын, гаилә багланышларын, гербларын, ул гербларның каян килеп чыгышына хәтле белә. Этикетны да бөтен вагы-төягенә чаклы белә; аңа эре җир биләүчеләрнең нинди хокуклары барлыгы да мәгълүм. Ул этләр һәм лачын беләнауга йөрү мәсьәләсеннән дә бик хәбәрдар, бервакыт зур осталык сорый торган шул кәсеп турында сүз чыккач, ул хәтта бу өлкәдә бик белдекле саналган король Людовик XIII не дә гаҗәпкә калдырган иде.

Шул заманның бай нәселдән чыккан барлык вельможалары кебек, ул бик шәп кылыч белән эш итә һәм ат өстендә йөри белә. Алай гына да түгел, ул чорда дворяннар бик сирәк укыган схоластик фәннәрдән дә аның мәгълүматы шулкадәр күп — Арамисның, белдеклелек күрсәтеп, Портос алдында латинча сүзләр куллануын ишетсә, Атос көлемсерәп кенә куя иде; Арамис берәр төрле грамматик ялгыш җибәргәч, Атосның ике-өч тапкыр хәтта, дусларын гаҗәпкә калдырып, фигыльне тиешле заманына, ә исемне тиешле килешенә куеп күрсәткәне дә бар. Ниһаять, хәрби кешеләр ансат кына диннәрен һәм вөҗданнарын саткан, сөяркәләрнең безнең чорга хас кырыс таләпчәнлеккә исе китмәгән, ярлылар ходайның җиденче әмерен бозган бер заманда Атос саф һәм пакь намуслы бер кеше иде. Кыскасы, башкалардан аерылыбрак торган үзенә бер төрле кеше иде ул.

Мәгәр шундый булуына да карамастан, нечкә күңелле, асыл затлы һәм зирәк акыллы бу адәм, карт кешеләр әкренләп физик һәм әхлакый яктан көчсезлеккә бирешкән кебек, үзе дә сизмәстән, көндәлек тормыш ихтыярына бирелеп китә. Аның күңеле төшенкеләнеп — Атосның андый чагы исә еш булгалый — аңардагы барлык нур сүнә, якты сирпеп торган матур сыйфатлары, куе караңгылыкка томалангандай, юкка чыга иде.

Илаһи зат юк була, ярым кеше генә торып кала. Атос, башын салындырып, сүзләрен көчкә-көчкә генә әйтеп, сүнгән-тонган күзләре белән сәгатьләр буе әле шешә белән стаканга, әле Гримога карап утыра. Аның һәрбер ишарәсенә буйсынырга гадәтләнгән хезмәтчесе, нәрсә кирәк икәнлеген хуҗасының җансыз күз карашыннан ук төшенеп алып, шундук ул теләгәнне үтәргә дә керешә. Әгәр инде дүрт дус Атосның кәефе шундый чагында җыелсалар, Атосның уртак гәпкә катнашуы көч-хәл белән генә әйтеп куйган ике-өч сүздән артмый. Аның каруы ул бер үзе дүрт кешелек шәраб эчә, ләкин үзенә моның әллә ни тәэсире сизелми — ул бары тик кашларын гына җыера төшә дә чырае гадәттәгедән сагышлырак кына була бара иде.

Д'Артаньян никадәр тырышса да (без аның бик кызыксынучан, зирәк акыллы егет икәнен яхшы беләбез), бу тирән күңел төшенкелегенең берәр сәбәбен таба алмады. Атос беркемнән бернинди хат алмый, дуслары белмәстәй бернинди эш-гамәл кылмый иде.

Бу сагышның сәбәбе шәрабта дип тә әйтеп булмый, чөнки, шәрапны ул, киресенчә, сагышын басар өчен дип эчә, мәгәр бу дару, әйткәнебезчә, аның сагышын көчәйтә генә төшә иде. Бу күңел төшенкелеген шакмак уеныннан дип тә булмый, чөнки кәефе килгәндә җырлый, кәефе киткәндә сүгенә-тиргәнә торган Портостан үзгә буларак, Атос уенда отса да, оттырса да, тыныч-сабыр булып кала иде. Бервакыт ул мушкетерлар белән уйнап утырганда бер кичтә мең пистоль акча отты, аннары шуны алтынлап чиккән җилкә каешы белән бергә кире оттырды, шуннан соң боларның барысын һәм тагын йөз луидорга арттырып яңадан отып алды, ләкин аның матур кара кашлары бер тапкыр да тетрәнмәде, куллары перламутр төсен югалтмады, шул кичтәге күңелле әңгәмә үзенең ямен, тынычлыгын җуймады.

Аның чыраендагы караңгылык, күршеләребез инглизләрдәге шикелле, явым-төшемгә бәйләнмәгән, чөнки Атосның бу сагышы елның иң матур чакларында тагы да көчәя төшә: июнь белән июль аның өчен иң авыр айлар була иде.

Атосның бүгенге көнгә бәйле кайгы-хәсрәте юк, киләчәк турында сөйләшә башласалар, ул җилкәсен генә сикертеп куя; димәк, аның күңел төшенкелегенең сәбәбе үткән көннәргә барып тоташа, бу хакта д'Артаньянга томанлы гына итеп башка дуслары да кинаяләгәне бар иде.

Үзен өретеп торган әнә шул серлелеге белән Атос тагы да кызыклырак кешедер кебек тоела, хәтта бөтенләй исереп җиткән чагында да, нинди генә четерекле сораулар бирсәң дә, аның күз карашы да, теле дә эчке серен фаш итми иде.

— Һай! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян.— Шәт, бичара Атос дөньяда да юктыр инде хәзер, минем аркада. Башын да, азагын да белмичә, үзе өчен бернинди файда өмет итмичә, фәкать минем хакка гына кереп буталды бит ул әлеге җанҗалга.

— Үзебезнең исән калуыбыз белән аңа бурычлы икәнлегебезне әйтәсе дә юк, әфәндем,— дип сүзгә Планше кушылды.— Аның ни дип кычкырганын хәтерлисезме: «Барыгыз, д'Артаньян! Мине эләктерделәр»,— диде. Шуннан соң ике пистолетыннан да атты да кылычын чак-чок китереп бик яман чыңлатырга кереште! Әйтерсең егерме кешегә каршы, дөресрәге — ажгырып ябырылган егерме җенгә каршы бер үзе сугышып калды!

Бу сүзләр д'Артаньянның йөрәк ярсуын бермә-бер көчәйтеп кенә җибәрде һәм ул болай да кушаяклап чапкан атын тагын да катырак чаптыра башлады.

Иртәнге сәгать унберләр тирәсендә юлчыларга Амьен күренде, уникенче яртыда инде алар әлеге нәләт төшкән трактирның ишегге төбенә килеп туктаганнар иде.

Д'Артаньянның мондагы хыянәтче трактирчыдан бик шәп итеп үч алу турында еш кына уйланганы да булды. Менә хәзер ул, безне сөендереп, шуны эшләргә тиеш иде. Шулай итеп, ул

эшләпәсен маңгаена басыбрак киде дә сул кулын кылыч сабына куеп, уң кулындагы камчысын селти-селти, трактирга килеп керде.

Бөгелә-сыгыла каршысына килгән трактир хуҗасыннан:

— Мине таныйсызмы? — дип сорады.

— Гафу итсәгез, галиҗәнап, танымыйм шул,— диде хуҗа, д'Артаньянның бик шәп корал-дирбиясенә шаккатып.

— Әһә, сез мине танымыйсыз!

— Юк шул, галиҗәнап.

— Алайса бер-ике сүз белән генә исегезгә төшерәм! Моннан ике атна чамасы элек сез бер дворянны ялган акча белән эш итә дип гаепләгән идегез. Сез аны нишләттегез?

Трактирчының йөзе агарынып китте, чөнки д'Артаньян бик хәтәр, усал бер кыяфәттә басып тора, өстәвенә Планше да нәкъ аның рәвешенә кергән иде.

— Һай, галиҗәнап, ул хакта әйтә генә күрмәгез миңа! — дип, кызганыч бер тавыш белән әйтеп куйды трактирчы.— И ходаем, ул ялгышым бик кыйммәткә төште шул миңа! Һай, бик бәхетсез кеше мин!

— «Ул дворянны нишләттегез?» — дип сорыйм мин сездән!

— Сүземне тыңлап кына бетерегезче, мәрхәмәтле галиҗәнап. Рәхим итеп, утырыгызчы.

Д'Артаньян, ачу-ярсуыннан һәм борчуларыннан сүзсез калып, хөкемдар кебек дәһшәтле бер кыяфәттә, креслога утырды. Планше исә мәгърур кыяфәттә аның креслосы артына барып басты.

Трактирчы, куркуыннан калтырана-калтырана:

— Ул хәл болай булды, галиҗәнап,— дип сүзендә дәвам итте.— Хәзер инде мин сезне таныдым. Сез әйткән дворян белән әлеге жанҗал башланган чакта китеп барган кеше сез идегез бит?

— Әйе, мин идем. Дөресен сөйләп бирмәсәгез, сезгә рәхим-шәфкать булмаячагын бик яхшы күреп торасыз.

— Алайса, рәхим итеп тыңлагызчы, мин сезгә, берсен дә яшермичә, бөтенесен сөйләп бирәм.

— Тыңлыйм.

— Начальство миңа хәбәр итте: минем трактирга берничә иптәше белән атаклы ялган акча коючы килеп төшәргә тиеш, өстәвенә, барысы да я гвардияче, я мушкетер киеме кигән булырлар, диде. Сез галиҗәнапларның атлары, хезмәтчеләре, киемнәре нинди икәнлеген — барысын да төп-төгәл итеп әйттеләр.

Д'Артаньян, бу төгәллекнең кайдан әйтелгәнлеген бик тиз төшенеп:

— Шуннан, шуннан? — диде.

— Шул сәбәпле, ярдәмгә алты солдат җибәргән начальствоның әмеренә буйсынып, мин ялган акча ясаучы дигән кешеләрне тоту өчен мәгъкуль санаган чараларны күрдем.

«Ялган акча ясаучы» дигән сүз кәефенә тигәнгә, д'Артаньян:

— Тагын шул! — дип куйды.

— Андый нәрсәләр сөйләгәнем өчен гафу итегез, галиҗәнап, тик минем акланыр сәбәбем дә шунда бит. Начальство мине бик нык куркытып әйтте, сез инде үзегез беләсез: трактирчы үзенең начальствосы белән тату яшәргә тиеш.

— Сездән тагын бер тапкыр сорыйм: кая куйдыгыз ул дворянны? Нишләттегез аны? Тереме ул, үлеме?

— Сабыр итегез, галиҗәнап, хәзер ул җиргә дә килеп җитәбез. Шулай итеп, әлеге сезгә мәгълүм хәл булды... Шул хәл сезнең ашыгыч рәвештә китеп баруыгызга да сәбәп булды шикелле,— дип әйтеп куйды хуҗа хәйләкәр генә бер төс белән. Д'Артаньян исә моны сизми калмады.— Шул дворян, сезнең дустыгыз, бик каты каршы торды. Хезмәтчесе, бәхетсезлеккә каршы, ат караучы булып киенгән солдатлар белән көтелмәгәндә талаш чыгарды.

— Ах син, җүнсез! — дип кычкырып җибәрде д'Артаньян.— Димәк, сез барыгыз да бер сүзле булгансыз. Ни сәбәптән мин сезнең бөтенегезнең дә башын бетерми торганмындыр!

— Юк, юк, галиҗәнап, кызганычка каршы, без барыбыз да бер сүзле түгел идек. Шулай икәнлегенә менә хәзер ышанырсыз. Сезнең дустыгыз (гафу итегез, аның, һичшиксез, хөрмәтле исеме бардыр, мин аны исеме белән атап әйтә алмыйм, чөнки ул исеме безгә мәгълүм түгел), димәк, сезнең дустыгыз, пистолетыннан ике солдатны атып екты да кылычы белән сугыша-сугыша чигенә башлады. Шул кылычы белән ул минем кешеләрнең берсен имгәтте, ә мине кылычының яны белән сугып һушымнан яздырды.

— Сөйләп бетерәсеңме син, юкмы, палач?! — дип кычкырды д'Артаньян.— Атос кайда? Ни булды Атоска?

— Әйткәнемчә, галиҗәнап, чигенә-чигенә ул подвалга төшә торган баскыч янына барып җитте. Подвал ишеге ачык иде. Шуның ачкычын алды да эчкә кереп бикләнде. Бөтен кеше: аннан ул беркая да китә алмый, диделәр, шуңа күрә беркем дә аңа шунда кереп бикләнергә комачауламады.

— Әлбәттә, сез бит аны үтерергә җыенмагансыз, сезгә аны ябып, өстеннән бикләп алырга гына кирәк булган! — диде д'Артаньян.

— Ай аллам, өстеннән бикләп алырга, имеш! Анттыр әгәр, галиҗәнап, үзен үзе бикләп куйды бит ул. Хәер, аңарчы әле ул тамаша да күрсәтте: бер солдатны кадап үтерде, икесен каты яралады.* Үлгән солдат белән ике яралыны иптәшләре алып киттеләр, шуннан ары мин аларның берсен дә белмим. Миңа килгәндә, мин һушыма килү белән губернатор җәнапларына янына барып, хәлне сөйләп бирдем дә: «Тоткынны нишләтергә?» — дип сорадым. Губернатор җәнаплары әйтерсең бу дөньяга айдан килеп төшкән: ни турында сөйләгәнегезне дә төшенмим, ди, сезгә килгән боерыкларны мин бирмәдем, ди, әгәр дә мәгәр сез, шул хәлләргә губернаторның да катнашы

бар дип берәр кешегә әйткән булсагыз, мин сезне тотып астырачакмын, ди, Күрәсез, әфәндем, мин ялгышып бер кеше урынына икенчене тотканмын, тотылырга тиешлесе качып котылган

— Я, Атос кайда? — дип кычкырып сорады д'Артаньян. Власть кешеләренең бу эшкә ничек караганлыкларын белгәч, аның ачуы тагы да көчәя төште.— Нишләттегез Атосны?

— Шуннан инде тоткын каршындагы гаебемне тизрәк йомшартасым килде,— дип сөйләвендә дәвам итте трактирчы.— мин, аны чыгарып җибәрим дип, баз янына килдем. Ай, әфәндем, кеше түгел, җенгә-диюгә әйләнгән иде ул. Үзенә ирек тәкъдим итүемә каршы ул, сезнең бу сүзегез хәйлә генә, үз шартларымны куймыйча мин моннан чыкмыйм, ди. Мин аңа тыныч кына җавап кайтардым — король хәзрәтләренең мушкетерына кул күтәреп, үземне нинди хәлгә куйганлыгымны аңлаган идем инде,— шулай итеп, мин аңа, сезнең шартларыгызны кабул итәргә әзермен, дип җавап бирдем.

«Иң элек хезмәтчемне бөтен кораллары белән минем янга кайтаруыгызны сорыйм», диде.

Аның бу боерыгы бик тиз җиренә җиткерелде: аңлыйсыздыр инде, әфәндем, сезнең дустыгыз ни теләсә, без шуны эшләргә әзер идек. Шулай итеп, Гримо әфәндене (сүзгә бик юмарт булмаса да, исемен әйтте анысы), Гримо әфәндене, яралы булуына карамастан, базга төшердек. Хуҗасы, аны үз янына кертеп, ишекне терәтте дә безгә үз урыныбызда калырга кушты.

— Я, әйтегез, кайда соң ул? Атос кайда? — дип кычкырды д'Артаньян.

— Базда ул, әфәндем.

— Ах, җүнсез, син әле һаман да аны базда тотасыңмыни?

— Алла сакласын! Юк, юк, әфәндем. Без аны базда тотар идекме соң? Сез аның анда, базда ниләр кылганлыгын белсәгез икән! Ай, әфәндем, әгәр дә сез аны шуннан чыгара алсагыз, мин сезгә гомерем буе рәхмәт укыр идем, җанымны саклаган фәрештә урынына күреп сезгә гыйбадәт кылыр идем.

— Андамы әле ул? Мин аны аннан таба аламмы?

— Әлбәттә, анда, әфәндем. Ул киреләнеп чыкмый ята. Без аңа көн саен, сәнәккә кадап, төннектән ипи сузабыз, сораганда ит тә бирәбез, тик төп азыгы ипи белән ит кенә түгел шул аның! Беркөнне, ике егетем белән, аска төшмәкче булып караган идем, ул бөтенләй ярсып ук китте. Ишетеп тордым: үзе пистолетларын, ә хезмәтчесе мушкетларын корырга керեште. Шуннан соң, нишләргә җыенасыз сез? — дип сорагач, дустыгыз: хезмәтчем белән икебезгә кырык тапкыр атарлык зарядыбыз бар, шуның кырыгын атып бетермичә, сезнең берегезне дә базга төшермибез, диде. Шуннан инде, әфәндем, губернаторга зарымны әйтергә бардым. Губернатор әйтте миңа: сезгә менә шул кирәк, трактирыгызга төшкән галиҗәнапларны мыскыл иткән өчен сабак булыр үзегезгә, диде.

Д'Артаньян, трактирчының кызганыч-мескен кыяфәтеннән көлеп җибәрәсе килеп:

— Шуннан бирле һаман шул хәлме? — дип сорады.

— Шуннан бирле һаман шул хәл,— диде трактирчы,— безнең хәл шәптән түгел, әфәндем, чөнки безнең бөтен азык-төлек базда саклана. Шешәле шәрап белән мичкәле шәрап та, сыра, үсемлек мае белән тәм-томнар да, дуңгыз мае белән колбасалар да — барысы шунда. Безгә аска төшү тыелган булганлыктан, үзебезгә килүче бөтен мосафирны такы-токы гына ашатырга-эчертергә туры килә, шул сәбәпле мосафирханәбез көннән-көн бөлә бара. Әгәр дустыгыз базда тагын бер генә атна ятса да, без бөтенләй бөлеп бетәчәкбез.

— Шул кирәк сиңа, мошенник. Безнең килеш-килбәтебезгә карап, ялган акча ясаучылар түгел, җүнле кешеләр икәнлегебезне чамаларлык түгел идемени?

— Шулай анысы, әфәндем, шулай, сүзегез хак,— диде трактир хуҗасы,— әнә ишетәсезме: тагын котырына башлады.

— Борчыганнардыр аны,— диде д'Артаньян.

— Нишләргә инде хәзер? — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды хуҗа.— Безгә ике бай инглиз килде бит әле.

— Килсә соң, ни булган?

— Ничек «ни булган»? Үзегез дә беләсез бит, әфәндем, инглизләр затлы шәрап ярата, ә болары иң яхшысын сорады. Хатыным шул әфәнделәргә сораган шәрапларын китерү өчен, Атос әфәндедән подвалга керергә рөхсәт сорагандыр да, дустыгыз, гадәтенчә, риза булмагандыр. И аллам! Тагын башланды инде мәхшәр!

Чыннан да, подвал ягыннан каты тавыш ишетелде. Д'Артаньян, урыныннан торып, тавыш килгән төшкә китте. Трактир хуҗасы, гаҗизлектән кулларын уа-уа, алдан атлады, Планше исә, мушкетын әзер тотып, хуҗасы артыннан иярде.

Инглизләрнең бик нык кәефләре киткән: алар, шактый юл килеп, ачыкканнар, сусаганнар иде. Алар беркадәр чит тел акценты белән, французча бик дөрес итеп:

— Көчләү була бит бу! Ул котырган адәм җүнле кешеләргә үз шәрапларына үзләре хуҗа булырга ирек бирми. Хәзер ишекне ватып керәбез, әгәр инде ул бөтенләй акылын җуйган икән, ул чагында без аны үтерәбез дә вәссәлам! — дип кычкыра башладылар.

— Тавышланмагыз, әфәнделәр! — диде аларга д'Артаньян, биленнән пистолетларын алып.— Гафу итәсез: сез беркемне дә үтермәячәксез.

Ишекнең эчке ягыннан Атосның тыныч-сабыр тавышы ишетелде:

— Яхшы, яхшы, кертегез ул мактанчыкларны, карап карарбыз.

Инглизләр, үзләре шактый батыр булсалар кирәк, шулай да икеләнеп калган кебек бер-берсенә карашып алдылар. Әйтер-

сеп базга кеше ашаучы бер гуж җан иясе, әкияттәге гыйфрит сыман бер нәрсә төшеп утырган да берәүне дә үзенең мәгарәсенә якын китерми иде.

Беравыкка бөтенесе тынып калды. Ахыр чиктә инглизләргә кире чигенү оят тоелды, күрәсең, арадан ачулырагы биш-алты басмалы баскычтан төшеп, таш стенаны да тишәрдәй бер көч белән бик каты итеп ишеккә китереп типте.

— Планше,— диде д'Артаньян, пистолетларының чакмаларын күтәреп,— мин әнә теге өстәгесен үземә алам, ә син астагысы белән шөгыльлән. Әфәнделәр, димәк, сез сугышырга телисез? Алай икән, бик шәп, сугышабыз!

Астан тоныкк кына булып Атос тавышы ишетелде:

— Йа раббым! Д'Артаньян тавышын ишетәм түгелме?!

Д'Артаньян да тавышын ишеттерергә тырышып әйтте:

— Ялгышмадың, дустым, нәкъ үзе булам,— диде.

— Бик яхшы! — диде Атос.— Алай булгач, без бу батырларны бик шәпләп эшкәртик әле.

Инглизләр кылычларын суырып чыгардылар, ләкин алар ике ут арасында калганнар иде. Чак кына икеләнеп тордылар, шулай да, беренче тапкырындагы кебек, горурлык тойгысы өстен чыкты, икенче тапкыр китереп тибүгә подвал ишеге буйдан-буйга ярылып китте.

— Читкәрәк кит, д'Артаньян, читкәрәк! Хәзер атам мин! — дип кычкырды Атос.

— Әфәнделәр! — диде д'Артаньян, аек акылын җуймыйча.— Үз хәлегез турында да уйлагыз... Чак кына сабыр итегез, Атос... Әфәнделәр, бик әшәке җанҗал чыгарасыз бит, пулялар белән тишкәләп бетерәчәкбез без сезне. Хезмәтчем белән икәү сезгә өч пуля җибәрәчәкбез, подвалдан да өчне алачаксыз. Өстәвенә әле, безнең кылычларыбыз да бар, мин дә, дустым да кылычны ярыйсы гына тота беләбез — анысы тәгаен. Сез миңа комачауламагыз, сезнең эшне дә, үзебезнекен дә үзем җайлармын. Хәзер сезгә шәрап китерерләр, анысына сүз бирәм.

Шунда Атосның:

— Ярый ла, шәрабы калган булса,— дип көлеп әйткәне ишетелде.

Трактирчы аркасына салкын тир бәреп чыкканын тойды.

— Ничек инде ул «шәрабы калган булса»? — дип пышылдады.

— Калгандыр, шайтан алгыры! — диде д'Артаньян.— Борчылмагыз, икәүләп бөтен базны эчеп бетерә алмаганнардыр әле. Әфәнделәр, кылычларыгызны урынына салып куегыз.

— Яхшы! Сез дә пистолетларыгызны билегезгә кыстырыгыз.

— Кыстырабыз.

Шулай дигәч, д'Артаньян башлап үрнәк күрсәтте. Аннары Планшега таба борылды да кулы белән ишарәләп мушкетын бушатырга кушты.

Инглизләр, бу хәлне күреп ышангач, мыгырданып тордылар

да кылычларын кыныларына салдылар. Д'Артаньян аларга Атосның ничек итеп подвалга ябылу вакыйгасын сөйләп бирде, инглизләр исә, чын джентльменнар булганлыктан, бу хәлгә трактирчының үзен генә гаепле санадылар.

— Ә хәзер, әфәнделәр, үз бүлмәгезгә менегез, бер ун минуттан сезгә ни кирәк — шуларның барысын да китерерләр,— диде д'Артаньян.

Инглизләр, баш иеп, өскә менеп киттеләр.

— Атос дус, хәзер мин үзем генә, ишекне ачыгызчы,— диде д'Артаньян.

— Хәзер ачам,— дип җавап бирде Атос.

Идәнгә шапылдап чыбык-чабык көлтәләре төшкәне, бүрәнәләр шыгырдаганы ишетелде: болар — Атосның контрэскарп һәм бастионнары, камалудагы батыр аларны үзе җимерә иде.

Беравыктан ишек әкренләп ачыла башлады, һәм ишек ярыгыннан Атосның ак чырае күренде; ул тиз-тиз генә тирә-ягына күз йөртеп чыкты.

Д'Артаньян, дусты каршына ташланып, аны кочаклап алды; шуннан соң Атосны бу юеш баздан алып чыга башлады, бары тик шул чагында гына ул дустының чайкалгалавына игътибар итте.

— Яраландыгызмы әллә? — дип сорады.

— Минме? Бернинди ярам юк. Ләх исерек мин, менә шул. Шуңа ирешү өчен кешенең әле беркайчан да бу кадәр тырышканы булмагандыр. Валлаһидыр, хуҗа, минем өлешкә йөз илледән шешә туры килгәндер.

— И аллам! — дип ут йотты хуҗа. — Хезмәтчесе әфәндесе эчкәннең яртысын гына эчкән булса да, мин тәмам бөлгәнмен дигән сүз бит бу.

— Гримо ул бик яхшы тәрбия алган, мин эчкәнне ук эчмәс. Ул мичкәдәгене генә эчте. Мичкә дигәннән, бөкесен тыгарга онытткан бугай ул. Әнә, ишетәсезме, нәрсәдер аккан тавыш бар?

Д'Артаньян шаркылдап көлеп җибәрде, трактир хуҗасы эсселе-суыклы булып китте.

Шул вакыт Атос артыннан җилкәсенә мушкетын салган Гримо да күренде; башы аның Рубенсның исерек сатирларыныкы шикелле чайкала иде. Егетнең өстенә алдан да, арттан да ниндидер куе май түгелгән,— трактир хуҗасы моның базындагы иң шәп зәйтүн мае икәнлеген чамалады.

Процессия зур зал аша узды да, хуҗадан рөхсәт-мазар сорап тормыйча, кунакханәнең иң яхшы бүлмәсенә кереп урнашты.

Ул арада трактирчы, хатыны белән, кулларына лампа тотып, тиз-тиз генә базга төшеп киттеләр һәм андагы йөрәк яргыч хәлне күреп шаккаттылар.

Стратегия сәнгатенең бөтен кагыйдәләренә туры китереп, чыбык-чабык бәйләмнәреннән, такта һәм буш мичкәләрдән

өслгән ныгытма аша Атос чыккан чакта ачкан тишектән әндә-сәндә идәнгә аккан май һәм шәрап эчендә ите ашалган бөт сөякләре күренә, базның сул почмагында исә ватык шешәләр өелеп ята; краны ябылмаган мичкәнең гүяки соңгы тамчы каны тамып тора. Борынгы бер шагыйрь әйтмешли, биредә, сугыш мәйданындагы кебек, үлеш-кырылыш хөкем сөрә иде.

Түшәм матчаларына асып куйган илле казылыкның уналабы гына исән калган иде.

Трактир хуҗасы белән хатынының аһ-зары подвал түшәме аша узып өскә дә ишетелде. Д'Артаньянның күңеленә бик хуш килде бу аваз. Атос исә башын да борып карамады.

Шулай да беравыктан бу аһ-зар ачу-ярсу белән алмашынды. Трактир хуҗасы, үз-үзен белештермәс бер хәлдә, кулына тимер шеш тотты да ике дус утырган бүлмәгә килеп керде.

Атос, аны күрү белән:

— Шәрап китерегез! — диде.

— Шәрап китерергә! Шәрап! — дип кычкырып җибәрде башы-күзе акайган хуҗа.— Сез эчкән шәрап йөз пистоль гына да түгел бит. Сез бит мине талагансыз, бөлдергәнсез, тамырымны корыткансыз!

— Юкны сөйләмәгез! Без әле сусыныбызны басарга да өлгермәдек,— диде Атос.

— Шәрапны гына эчкән булсагыз бер хәл иде әле, өстәвенә бөтен шешәләрне ватып бетергәнсез!

— Сез үзегез мине шешә өеменә төртеп аудардыгыз да — ул ишелде. Үзегез гаепле.

— Бөтен маемны түгеп бетергәнсез!

— Май ул — ярага сөртү өчен бик шәп дәва. Бичара Гримога үзегез ясаган яраларын дәваларга кирәк ләбаса.

— Бөтен казылыкларымны кимереп бетергәнсез!

— Ул базда мыжлаган күсе.

— Шуларның барысы өчен дә акча түләрсез! — дип кычкырды хуҗа, чыгырыннан чыгып.

— Җүнсезнең җүнсезе! — диде Атос, урыныннан кузгала башлап, ләкин шундук лып итеп кире утырды: аның инде кымшаныр лык та хәле калмаган иде. Д'Артаньян, дустына ярдәмгә килеп, камчысын алып куйды.

Трактир хуҗасы бер адым арткарак чикте дә зарланыргашыңшырга кереште.

— Моннан ары ходай китергән кунакларыгызга мөлаемрак булырсыз,— диде д'Артаньян.

— Ходай китергән, имеш! Ичмасам, җен китергән, диегез инде!

— Менә нәрсә, сөеклем,— диде аңа д'Артаньян янап,— әгәр дә мәгәр чәпчүеңнән туктамасаң, хәзер дүртәүләшеп базыңа төшеп бикләнәбез дә күпме зарар ясалганлыгын карап карыйбыз.

— Риза-бәхил, эфәнделәр, риза-бәхил,— диде хуҗа, куркуга

төшен,— үзем гаеплемен, гаебемне танийм, кичерелмәслек гаеп булмый бит инде. Сез бай галиҗәнаплар, ә мин ярлы бер трактирчы, шулай булгач сез мине кызганырга тиеш инде.

— Ә менә монысы башка сүз,— диде Атос,— болай булса, син минем күңелемне нечкәртеп җибәреп, мичкәләреңнән аккан шәрап шикелле, күз яшьләремне агызырсың. Без алай бик куркыныч кешеләр түгел. Якынрак кил, бераз сөйләшик.

Хуҗа шикләнә-шикләнә генә якынрак килде.

— Якынрак кил, дим, курыкма,— диде Атос.— Мин акча түләргә дип җыенгач, янчыгымны өстәлгә куйган идем.

— Бик дөрес, әфәндем.

— Шул янчыкта алтмыш пистоль акча бар иде, кайда ул?

— Суд канцеляриясенә тапшырылды, әфәндем, чөнки миңа аны ялган акча диделәр.

— Менә шул: янчыкны кире сорап ал да шул алтмыш пистоль акча сиңа калыр.

— Әфәндем, үз кулларына кергән малны суд чиновникларының кире кайтармауларын бик яхшы беләсез бит. Ялган акча булса әле, кире кайтарырлар дип өметләнер дә идең, бәхетсезлеккә каршы, чын иде шул ул акчалар.

— Суд белән теләсәң ничек сөйләш-килеш, дустым, анысы миңа кагылмый, минем хәзер бер ливр да акчам юк.

— Менә нәрсә,— дип сүзгә д'Артаньян да кушылды.— Атосның аты кайда хәзер?

— Абзарда.

— Күпме тора ул?

— Илле пистоль, шуннан да артык түгел.

— Әйтик, сиксән пистольдән дә ким түгел аның бәясе. Атны үзеңә аласың да шуның белән вәссәләм.

— Ничек ул алай?! Син минем атны сатасыңмы? Минем Баязетны? — диде Атос, гаҗәпкә калып.— Ә мин нәрсәгә атланып походка чыгармын соң, Гримога атланыппмы?

— Мин сиңа бүтән ат алып килдем,— диде д'Артаньян.

— Бүтән ат?

— Бер дигән ат! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды хуҗа.

— Алайса, икенчесе бар икән, яшьрәк тә икән, картын үзеңә ал да безгә шәрап китер.

— Ниндине? — дип сорады хуҗа, тәмам тынычланып.

— Баз түрендә, рәшәткә буендагысын. Анда тагын егерме биш шешә калган иде әле, башкалары мин егылганда ватылды. Алтыны китер.

— Кеше түгел, төпсез мичкәдер бу,— дип үзалдына мыгырданды хуҗа.— Монда тагын ике атна торып, эчкәне өчен акча түләсә, минем эшләр рәтләнеп китәр иде китүен.

— Инглиз әфәнделәргә дә шундый ук дүрт шешә шәрап китерергә онытма,— дип өстәде д'Артаньян.

— Ә хәзер, шәрап көткән арада, башкаларга ни булганын сөйлә инде, д'Артаньян,— диде Атос.

Д'Артаньян Портосны аягын тайдырып урын өстендә ят-кан, Арамисны исә ике дин әһеле белән сөйләшеп утырган хәлендә табуын сөйләп бирде. Ул сүзен бетергәндә трактир хуҗасы әйтелгән шәраплар белән бот ите китерде,— бәхеткә каршы, бу ит, баздан башка, икенче җирдә калган булган икән

Атос, үзенә дә, д'Артаньянга да шәрап сала-сала:

— Бик яхшы, Портос белән Арамисны әйтәм,— диде.—Ә үзегез соң, дустым, үзегезнең эшләр ничек, сезнең үзегез белән ниләр булып бетте? Минемчә, сезнең кәефегез бик начар.

— Кызганычка каршы, моның сәбәбе шул: арабызда иң бәхетсез бер кеше икәнмен мин! — дип җавап бирде д'Артаньян.

— Д'Артаньян, син бәхетсез! — дип, Атос кычкыра төшеп әйтеп куйды.— Ни булды соң? Сөйләп бирче.

— Соңыннан сөйләрмен.

— Соңыннан, имеш! Ә нигә хәзер үк түгел? Син мине исе-рек дисеңмени? Шуны бел, дустым: минем акылның иң аек чагы шәрап эчеп утырганда була. Сөйлә инде, мин бөтен дикъкатем белән тыңларга әзермен.

Шуннан д'Артаньян Бонасье ханым белән булган хәлне сөй-ләде.

Атос аны сабыр гына тыңлап утырды да:

— Искитәрлек нәрсә түгел лә, бөтенләй юк нәрсә,— дип куйды.

Атосның «юк нәрсә» дигәне иң яраткан бер сүзе иде.

— Сез барысына да юк нәрсә дип кенә карыйсыз, Атос дус,— диде бу сүзгә каршы д'Артаньян,— үзе бер дә хатын-кыз сөеп карамаган кешенең мондый сүзе ышандырмый шул.

Атосның сүнгән-сүрелгән күз карашы шунда кинәт кабынып чаткыланып китте, тик бу хәл озакка бармады. аның карашы, элекке шикелле, яңадан тоныклана-томанлана башлады.

— Дөрес анысы, минем хатын-кыз сөеп караганым юк,— дип куйды ул сабыр гына.

— Алай булгач, сез, таш бәгырь, без йомшак бәгырьлеләрне гаепләп хаклы түгел икәнлегегезне күреп торасыз.

— Йомшак бәгырь — яралы бәгырь ул,— диде Атос.

— Ягъни, сез ни димәкче буласыз?

— Шулай димәкче булам: мәхәббәт ул — лотерея, анда оту-чы — үзенә үлем ота! Сез, д'Артаньян дус, оттырып бик бәхет-ле булгансыз, ихластыр әгәр. Һәрвакыт шулай оттырып ки-легез, минем сезгә киңәшем шул.

— Минемчә, ул ханым мине бик ярата шикелле иде!

— Шулай тоелган гына ул сезгә.

— Юк, мине чыннан да ярата иде ул.

— Сабый! Сезнең шикелле барлык ирләр дә: сөйгән ярым мине өзелеп ярата, дип ышана шул, ә үзләрен сөяркәләре алдый.

— Бу исәпкә сез кермисез инде, Атос, сезнең бит гомерегез-дә дә сөйгән ярыгыз булмаган.

— Дөрес анысы,— диде Атос, беравык дәшми торганнан соң,— минем гомеремдә дә сөйгән ярым булмады. Әйдә эчеп җибәрик әле!

— Алай булгач, философ дус, мине өйрәтегез, ярдәм итегез инде мина, мин акыл-киңәш һәм юаныч эзлим.

— Юаныч? Нәрсәдән?

— Бәхетсезлегемнән.

— Сезнең бәхетсезлек көлке генә ул,— диде Атос, җилкәсен сикертеп.— Мин менә белер идем: әгәр мин сезгә бер мәхәббәт тарихын сөйләп бирсәм, сез нәрсә дияр идегез икән?

— Үзегез кичергәнме?

— Минме, я булмаса минем берәр дустыммы — анысы барыбер түгелмени?

— Сөйләгез әле, Атос, сөйләгез әле.

— Башта эчеп куйыйк, шулай яхшырак булыр.

— Эчә-эчә сөйләгез.

— Чыннан да, бу ике эшнең икесен берьюлы эшләргә була бит,— диде Атос, үз стаканын эчеп куйды да яңадан шәрап салды.

— Тыңлыйм,— диде д'Артаньян.

Атос уйга калды, һәм уйларына бирелә барган саен д'Артаньян күз алдында аның йөзе агарына барды; Атосның исереклеге инде гадәттәге исерек кеше авып, йокыга китәрлек чамада иде. Ә ул уяу хәлендә саташып утыра сыман иде. Бу исереклек саташуының нинди дер куркыныч, яман ягы да бар сыман иде.

— Сезнең инде бик сөйләтәсегез киләме? — дип сорады ул.

— Бик үтенеп сорыйм,— диде д'Артаньян.

— Ярый, алайса, сезнеңчә булсын. Дусларымнан берәү... мин түгел, дусларымнан берәү, исегездә тотыгыз! — диде Атос күңелсез генә елмаеп,— мин туган провинциядән, ягъни Берридан, бер граф, Дандоло яисә Моңморанси кебек үк атаклы бер кеше, егерме биш яшендә уналты яшьлек бер кызга гашыйк була. Кыз мәхәббәтнең үзе шикелле гүзәл була. Яшенә хас балачыллыгы, беркатлылыгы белән бергә, моңардан хатын-кызга хас булмаган зирәк-тапкыр акыл да, шагыйрь акылы да сизелеп тора: сеткә ошау гына түгел, мәхәббәттән исертә ул аны. Кыз рухани абыйсы белән кечкенә генә бер местечкода яши. Икесе дә бу якка каяндыр күчеп килгән булганнар; аларның каян килгәнлекләрен беркем белми, кыз бик чибәр, абыйсы рухани булгач, аларның каян килгәнлеген сорау турында берәү дә уйламый. Хәер, имеш-мимешләргә караганда, яхшы гаиләдән чыккан булырга тиеш алар. Минем дустым, ул җирләрнең хуҗасы, кызны ансат кына үзенә карата, я булмаса, көчләп ала да ала, чөнки ул монда бөтенесенә үзе хуҗа, беркем белмәгән чит-ят кешеләрне кем яклап маташсын икән? Бәхетсезлегенә каршы, ул бик намуслы кеше була шул, кызга өйләнә. Ахмак, дивана, ишәк!

— Нигә алай дисез, кызны яраткан бит ул? — диде д'Артаньян.

— Сабыр итегез,— диде Атос.— Кызны ул, үзенең замогына алып китеп, бөтен провинциядә беренче дама итә. Дөресен әйтергә кирәк — кыз үз ролен бик яхшы башкара.

— Я, шуннан соң инде ни була? — дип сорады д'Артаньян.

— Шуннан соң ни буламы?! Беркөнне ирс белән бергә ауга чыккач,— дип Атос әкрен бер тавыш белән кызу-кызу сөйләп китте,— аттан егылып төшеп, аңын җуя. Граф йөгереп килеп ярдәм итәргә керешә, күлмәген кысып уңайсызлап торганга күрә, граф аны хәнҗәре белән аерып ташлый да кызның кулбашлары ачылып китә. Әйтегез әле, д'Артаньян, кызның кулбашында нәрсә булган дип уйлыйсыз? — диде Атос шаркылдап көлә-көлә.

— Анысын каян белим инде мин? — диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Кызга ләлә чәчкәсе, хурлык тамгасы суккан булганнар,— диде Атос.

— Коточкыч хәл бит бу! Алай булуы мөмкин түгел! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян.

— Менә шулай шул, дустым. Фәрештә дигәнебез иблис булып чыккан. Бичара кыз карак икән.

— Шуннан граф нишләгән инде?

— Граф үз җирендә власте чикләнмәгән хуҗа була, ул андагы кешеләрне, теләсә, җәзалый да, кичерә дә ала; ул графиняның күлмәген бөтенләй аерып ташлый да, кулларын артка каерып бәйләп, агачка асып куя.

— Йа хода, Атос! Кеше үтерү була бит бу! — дип кычкырып куйды д'Артаньян.

— Әйе, кеше үтерү шул, бары шул гына,— диде Атос, үлек төсле агарынып.— Тукта; минем шәрабым беткән икән.

Шулай дигәч, Атос соңгы шешәне алып авызына күтәрде дә, стаканнан эчкән шикелле генә, бер тын белән эчеп тә куйды.

Аннары башын кулларына салды. Д'Артаньян, коты очып, аның каршында басып тора бирде.

— Шушы хәл мине чибәр, шигъриятле һәм гашыйк хатын-кызларны сөю чиреннән дәвалады,— диде Атос яңадан тураеп, граф турындагы хикәятен ул әле тәмамларга җыенмый иде ахры.— Сезгә дә шуны ук телим. Әйдә эчеп куйыйк!

— Кыз үлгәнме инде? — дип мыгырданып куйды д'Артаньян.

— Әлбәттә! — диде Атос.— Стаканыгызны бирегез әле. Каклаган дуңгыз ите китер, хөрәсән! — дип кычкырды Атос хуҗага.— Безнең бүтән эчәрлек чама калмады!

— Ә кызның абыйсы? — дип курка-курка гына сорады д'Артаньян.

— Абыйсы? — дип кайтарып сорады Атос.

— Әйе, рухани?

— Ә, рухани! Мин анысын да асарга кушмакчы идем дә, ул житезрәк булып чыкты, мәхәлләсеннән китеп өлгергән.

— Соңыннан да шул җүнсез бәндәнең кем икәнлеген белә алмадыгызмы?

— Чибәр кызның беренче сөйгән егете, кәсептәше, аның үз ише булган, күрәсең. Аның руханилыгы да сөяркәсен кияүгә биреп, бәхетле итү өчен генә булгандыр. Аның аяк-кулларын кисеп үтергәннәрдер дип уйлыйм.

— Йа хода, йа хода! — диде д'Артаньян әлеге коточкыч хикәяттән бөтен җаны тетрәнеп.

— Нигә ит ашамыйсыз, д'Артаньян? Бик шәп бит,— диде Атос, бер кисәк ит кисеп, егетнең тәлинкәсенә салды.— Бик кызганыч: базда шушындый өч-дүрт кисәк бот ите булмады! Тагын илле шешә эчкән булыр идем.

Д'Артаньянның инде бу әңгәмәне дәвам иттерерлек хәле калмаган: ул үзен акылдан язып барган сыман хис кыла иде. Шуңа күрә егет башын куллары өстенә салды да йоклап киткәнгә сабышты.

— Яшьләр эчә белми шул хәзер, бусы иң яхшыларыннан санала бит әле! — диде Атос, үкенечле бер төс белән егеткә күз салып.

## XXVIII

## КАЙТУ

Атос сөйләгән куркыныч хикәят д'Артаньянның бөтен җанын тетрәтте; шулай да яртылаш кына чишелгән бу сернең әле күп ягы егеткә аңлашылып бетмәде; иң элек, ул серне тәмам исереп җиткән кеше ярым исерек кешегә сөйләде; әмма ике-өч шешә бургунд шәрабы эчкәннән соң башта шуның томаны йөзсә дә, д'Артаньян, икенче көнне иртән йокысыннан уянгач, кичәге хикәятнең һәр сүзен шулкадәр ачык хәтерләде, гүяки ул сүзләр бер-бер артлы тезелешеп аның миенә язылып калган иде. Аңлашылып бетмәгәннәре аңарда бары тик беләсе килү теләге генә уятты, һәм ул кичәге әңгәмәне яңартып җибәрергә дигән катгый бер ният белән дусты янына китте, ләкин Атос инде тәмам айнып җиткән, ягъни башкалар күңелендәген барысын да күрә, ә үз күңелен ачмый торган бер кеше булып калган иде.

Хәер, кул бирешеп күрешкәннән соң, мушкетер үзе д'Артаньяннан алдарак әйтеп өлгерде.

— Кичә мин бик каты исереп киткәнмен, дустым,— дип сүзгә башлады ул,— шул хәлне бүген иртән уянгач сиздем: телем көчкә-көчкә генә әйләнә, йөрәгем дә һаман каты тибә әле. Валлаһи, мин сезгә әлләниләр сөйләп бетергәнмен бугай.

Шулай дигәч, ул дустына туп-туры текәлеп карады — тегесе уңайсызланып китте.

— Юк ла, хәтерем ялгышмаса, сез искитәрлек әллә ни сөйләмәдегез шикелле,— диде д'Артаньян аның бу сүзенә каршы.

— Шулаймыни? Монысы бик гаҗәп. Ә мин тагын сезгә бер бик күңелсез хәл сөйләгәнмен кебек тоелган иде.

Шулай дигәч, Атос, егетнең күңел түренә үк күз салырга теләгәндәй, тагын текәлеп карады.

— Мөгаен, мин сездән дә артыграк исереп киткәнмендер: берни хәтерләмим.

Ләкин мондый сүз генә Атосны канәгатьләндереп бетермәде, ул сөйләнүендә дәвам итте:

— Сезнең, әлбәттә, игътибар иткәнегез бардыр, дустым,— һәркем үзенчә исерә: берәүләр күңелсезләнеп кала, икенче берәүләрнең кәефе күтәрелеп китә; мин, мәсәлән, эчкәч, күңелсезләккә бирелеп, кайчандыр надан имчәк анамнан ишеткән куркыныч хәлләрне сөйләргә яратам. Минем кимчелегем ул, турысын әйтим: бик зур кимчелегем. Әгәр шуны ташласам, аракы эчә беләм дигән сүз.

Атос моны шундый ихлас, табигый итеп сөйли иде — д'Артаньянның теге ышанычы какшый башлаган кебек булды.

— Әйе шул, чыннан да,— диде егет, тагын күңеленнән ычкына башлаган хакыйкатьне тотып калырга тырышып,— төштә күргән кебек кенә хәтерлим шикелле: без ниндидер асылган кешеләр турында сөйләштек бугай.

— Әһә! Менә бит! — диде Атос, йөзе агарынып китте, үзе көчәнеп булса да елмаерга тырышты.— Шулай шул: мин гел асылган кешеләр белән саташам.

— Әйе, әйе, исемә төшә башлады,— диде д'Артаньян,— әйе, ни, туктагыз әле... без бер хатын-кыз турында сөйләштек шикелле...

— Шулайдыр дип уйлаган идем,— диде Атос, чырае үлекнеке төсле агарынып китте,— аксыл-сары чәчле хатын турындагысы минем гел сөйли торган сүзем. Шуны сөйләргә керештемме инде, мин ләх исерек дигән сүз.

— Дөрес, аксыл-сары чәчле, озын буйлы, зәңгәр күзле чибәр бер хатын турында сөйләдегез,— диде д'Артаньян.

— Әйе, шулай, асып та үтерелгән ул.

— Ире асып үтергән, сезнең танышларыгыздан бай бер әфәнде,— дип өстәде д'Артаньян, Атоска текәлеп карап.

— Менә, күрдегезме инде, ни сөйләгәненне белми сөйләсәң, кешегә куләгә төшерүе дә бик җиңел бит,— диде Атос, узалдына үкенгәндәй җилкәсен сикертеп куйды.— Ярый, моннан ары артыгын эчмәм, д'Артаньян, бик начар гадәт ул.

Д'Артаньян ни дип тә җавап кайтармады.

— Шуны әйтим әле,— диде Атос, икенче сүзгә күчеп,— миңа алып килгән атыгыз өчен бик зур рәхмәт.

— Сезгә ошадымы соң? — дип сорады д'Артаньян.

— Ошавын ошады да, тик чыдамлыгы әллә ни түгел бугай.

— Ялгышасыз. Мин ул атта барлы-юклы сәгать ярым эчен-

лә ун лье юл уздым. Шуннан соң да әле аның кыяфәте Сен-Сюльпис мәйданын урап килгән шикелле генә иде.

— Алай икән! Ул чагында миңа үкенергә генә каладыр инде?

— Үкенергә?

— Әйе, ул ат минем кулдан китте шул инде.

— Ничек ул алай?

— Эш болай булды: бүген иртән мин сәгать алтыда ук уяндым, сез үлгән кебек йоклап ята идегез; ә минем берничнди шөгылем юк; әле кичәге сыйлардан да айнып җитмәгән идем. Шулай итеп, мин залга төштем, анда теге инглизләрнең берсе барышник белән ат сатулашып тора иде — кичә аның аты янып үлгән икән. Мин аның янына килеп, сүзләренә колак салдым: тегенең җирән алашасына йөз пистоль бирәм, ди бу. «Беләсезме, әфәндем, миндә дә сатлык ат бар»,— дидем мин моңа.

«Кичә дустыгызның хезмәтчесе тотып торган ат булса, бик шәп ат ул»,— ди бу.

«Сезнеңчә ничек, йөз пистоль бирерлекме аңа?» — дим.

«Бирерлек,— ди.— Сез аны миңа шул бәягә бирәсезме соң?» — ди.

«Юк, мин әйтәм, уенга ставка итеп куям»,— дим.

«Уйныйбызмыни?» — ди бу.

«Шакмак уйныйбыз»,— мин әйтәм.

Шулай итеп, килештек, уйнадык та атны оттырдым мин. Аның каруы иярне кайтарып отып алдым.

Д'Артаньян ризасызланып чыраен сытты.

— Сезгә ошамыймыни? — дип сорады Атос.

— Турысын әйткәндә, ошамый,— диде д'Артаньян.— Сугыш көнендә безне шул атларыбыздан күреп танырга тиешләр иде. Үзенә күрә бер бүләк, ихтирам билгесе иде ул. Юкка алай иткәнсез, Атос.

— Юкны сөйләмәгез әле, дустым, менә минем урынга куеп карагыз үзегезне,— диде мушкетер,— эч пошудан үземне-үзем кая куярга белми йөри идем, аннары, дөресен генә әйткәндә, мин инглиз атларын яратып та бетермим. Әгәр бөтен хикмәт кемгәдер безне танырга кирәклектә генә булса, моның өчен ияр дә җитә бит,— шактый ерактан күренә ул. Атка килгәндә, без аның юкка чыгуына сәбәп табарбыз. Соң, атлар да үлми тормый лабаса! Әйтик, минем ат маңка авыруыннан яки корчаңгыдан үлеп китте ди.

Д'Артаньян һаман йомшамады.

— Кызганыч, сезгә ул хайван бик кадерле булган, күрәсең, шулай да мин хәлне сөйләп бетермәдем әле,— диде Атос.

— Тагын нәрсәләр маташтырдыгыз?

— Үз атымны оттыргач,— унга тугыз белән, шәпме? — сезнең атка уйныйм әле дигән уй килде башка.

— Бу уегызны чынга ашырмагансыздыр дип беләм?

— Киресенчә, шундук эшләдем мин аны.

— Я, шуннан? — дип кычкыра төшеп сорады д'Артаньян әсәрләнеп.

— Шуннан уйнадым да оттырдым.

— Минем атны дамы?

— Сезнең атны да — сигезгә җиде белән. Нибары бер очко аркасында... Шундый бер мәкальне беләсезме?

— Атос, акылдан язгансыз сез, валлаһи!

— Беләсезме, д'Артаньян дус, бу сүзне мина бүген түгел, кичә мин сезгә тузга язмаган нәрсәләр сөйләп утырган чакта әйтергә кирәк иде. Мин ул атны бөтен булырдай булган дирбияләре белән оттырдым.

— Коточкыч хәл бит бу!

— Туктагыз әле, мин сезгә әйтеп бетермәдем бит әле. Мин чама белән уйнасам, бик шәп уенчы булыр идем, тик, эчкән чактагы шикелле, чаманы югалтып җибәрәм шул мин, менә бу юлы да шулай.

— Тагын нәрсәгә уйнадыгыз? Сезнең бит инде уйнарлык әйберегез дә калмаган.

— Дөрес түгел, дустым, дөрес түгел, безнең әле сезнең бармагыгызда елкылдап торган менә бу асылташыбыз бар, кичә мин аны күргән идем.

— Бу асылташ! — дип кычкырып куйды д'Артаньян, кабаланып бармагын капшарга кереште.

— Заманында минем үземнең дә асылташларым бар иде, мин аларның бәһасын беләм, шуңа күрә мин аның бәһасын мең пистоль итеп куйдым.

Д'Артаньян, куркуыннан ярым үле, ярым тере хәлендә, коры гына итеп сорады:

— Сез минем асылташ турында ләм-мим сүз чыгармагансыздыр дип беләм?

— Киресенчә, дустым. Шуны белегез: бу асылташ хәзер безнең бердәнбер өметебез иде, мин, аны уенга куеп, дирбияләрне, атларны, шуның өстенә юллык акча да отып ала ала идем.

— Атос, йөрәгем ярыла минем! — дип кычкырды д'Артаньян.

— Шулай итеп, мин партнерыма сезнең асылташ хакында әйттем. Ул үзе дә сезнең асылташка игътибар иткән булган икән инде. Чыннан да, дустым, шулай. Сез бармагыгызда йолдыз нуры уйнатып йөрегез дә аны берәү дә күрмәсенме? Шайтаным! Мөмкин түгел ул!

— Ярар, җитәр, дустым, җитәр! Сезнең бу сабырлыгыгыз үтерә мине, валлаһи! — диде д'Артаньян.

— Шулай итеп, без бу асылташны йөзәр пистольдән ун уенга бүлдек.

— Алаймыни, сезнең әле һаман мине шаяртасыгыз, газаплыйсыгыз киләме? — диде д'Артаньян, «Илиада»да Минерва Ахиллны эләктереп алган кебек, ачу-ярсуы аны да чәченнән тотып алган иде.

— Юк, шаяртмыйм мин, шайтан алгыры! Минем урында булсагыз, сез нишләр идегез икән — менә шуны күрер идем мин! Ике атна буена мин бер кеше чырае күрмәдем, шешәләр белән генә серләшә-серләшә кыргыйлашып беттем.

— Минем асылташны уенга салу өчен сәбәп була алмый бит әле ул,— диде моңа каршы д'Артаньян, кулын чытырдатып кыса-кыса.

— Соң, тыңлап бетерегез инде. Йөзәр пистольдән ун уенга бүлдек. Ун йөрешкә кадәр кайтарып оту хокукыннан башка. Унөченче йөрештә, унөченче ударда бөтенесен оттырдым мин — унөч саны минем өчен һәркайчан тәкъдир саны иде ул. Нәкъ унөченче июль көнне...

— Шайтаным! — дип кычкырды д'Артаньян, өстәл яныннан кузгалып. Бүгенге бу хәл кичәгесен оныттырган иде инде.

— Сабыр ит әле,— диде Атос,— минем үз планым бар иде. Инглиз — чудак ул. Иртә белән мин аның Гримо белән сөйләшеп торганын күрдем. Гримо әйтте миңа: инглиз аңа хезмәтче булып күчәргә тәкъдим иткән икән. Шуннан инде мин уенга Гримоны куйдым, сүзсез-өнсез Гримоны ун уенга бүлеп.

— Менә монысын бик оста эшләгәнсез! — диде д'Артаньян, түзмичә шаркылдап көлеп җибәрде.

— Уенга Гримоны куйдым, Гримоны, ишетәсезме? Гримо үзе бер дукатон бәясе тормаса да, аның ун ставкасы ярдәмендә мин асылташны кире отып алдым. Менә шуннан соң әйтегез инде: үзсүзлелек яхшы сыйфат түгелме?

Д'Артаньян, эчен тотып көлә-көлә:

— Валлаһи, бик мәзәк бит бу! — дип куйды.

— Сез, әлбәттә, төшенәсез инде: кул бер кызып киткәч, мин шундук яңадан асылташка уйнарга керештем.

— Алай икән,— дип куйды д'Артаньян, чырае тагын караңгыланып китте.

— Сезнең иярегезне кире отып алдым, аннары атыгызны, шуннан соң үз ияремне, аннары үз атымны, шуннан соң тагы оттырдым. Кыскасы, мин яңадан сезнең иярне эләктердем, аннары үземнекен. Эшләр менә шулай. Искиткеч шәп йөреш булды ул, шунда инде мин чик куйдым.

Д'Артаньян, иң өстеннән бөтен трактир авырлыгы төшеп киткән кебек, «уф!» дип җиңел сулап куйды. Кыяр-кыймас кына:

— Алайса, асылташ минем карамакта кала әле? — дип сорады.

— Бөтенләе белән сезнең карамакта кала, дустым, өстәвенә әле безнең Буцефалларның иярләре дә үзебездә кала.

— Атлары булмагач, иярләре нәрсәгә кирәк?

— Бу мәсьәләдә минем бер идеям бар.

— Атос, сез мине куркытасыз.

— Карагыз әле, д'Артаньян, сезнең күптән уйнаганыгыз юк бугай инде, әйеме?

— Уйнарга тамчы да теләгем юк.

— Алай дип өзеп әйтмәгез әле. Шулай итеп, сезнең күптән уйнаганыгыз юк, димәк, сезнең уеннан бәхет булырга тиеш, дим.

— Шулай да булсын ди! Я, шуннан нәрсә?

— Шуннанмы? Теге инглиз, юлдашы белән, һаман монда бит әле. Мин аның нярләрне бик кызганганын сиздем. Ә сезгә атыгыз бик кадерле шикелле. Мин сезнең урында булсам, атка каршы нярне куеп уйнар идем.

— Ә ул бер ияргә генә уйнарга риза булмас бит.

— Шайтаным икән, соң икесен дә куй! Мин алай сезнең кебек саран түгел.

Д'Артаньян, ирексездән аның коткысына бирелә башлап, кыяр-кыймас кына:

— Сез шулай эшләр идегезме соң? — дип сорады.

— Валлаһи, нибары бер генә йөреш.

— Беләсезме, инде атсыз калгач, иярсез дә каласым килми минем.

— Алайса уенга асылташыгызны куегыз.

— О, анысы башка мәсьәлә,— гомеремдә дә куймаячакмын!

— Шайтан алгыры! — дип куйды Атос.— Мин сезгә Планшены куеп карагыз дип тә әйтер идем дә, бер тапкыр андый хәл булгач, теге инглиз риза булмастыр шул.

— Беләсезме, Атос дускай, минем бернәрсәне дә тәвәккәлләргә исәбем юк,— диде д'Артаньян.

— Кызганыч,— диде Атос салкын гына.— Инглизнең кесәсе тулы пистоль. И аллам, ичмасам, бер генә йөрешкә тәвәккәллэгез инде! Бер йөреш — нибары бер минутлык эш бит ул.

— Әгәр оттырсам?

— Отасыз.

— Әгәр дә мәгәр оттырсам?

— Оттырсагыз, ияр.ләрне китереп бирәсез.

— Ярый, каян килеп кая китмәгән — бер йөреш! — диде д'Артаньян.

Атос, инглизне эзли китеп, аны абзардан барып тапты: инглиз кешесе бик сокланып-ымсынып иярләрне карап тора иде. Сүз башлау өчен бик җайлы чак иде. Атос үзенең шартларын әйтте: ике ияргә бер ат яки йөз пистоль акча — икесенең берсе, диде. Инглиз тиз генә исәпләп алды: ике ияр икесе бергә өч йөз пистоль торырлык иде. Моңа бик риза булды.

Д'Артаньян калтырана-калтырана шакмакны ташлады, өч очко төште; Атос, аның чырае агарганлыгын күреп, куркып китте һәм:

— Әйбәт йөреш түгел, дустым. Сез, әфәндем, атларны бөтен дирбияләре белән аласыз,— дип кенә куйды.

Үзенең отачагын тоеп торган инглиз хәтта шакмакларны болгатып та маташмады; җиңәчәгенә ышанычы шулкадәр зур иде — карамый-нитми генә шакмакларны өстәл өстенә ташла-

ды; д'Артаньян, кәефе киткәнлеген сиздермәс өчен, башын читкә борды.

— Менә хикмәт,— дип гадәтенчә тыныч кына сөйләнеп куйды Атос,— нинди гаҗәп йөреш, минем моны бөтен гомерем буена да нибары дүрт кенә тапкыр күргәнем бар: бер дә бер — ике очко!

Инглиз әйләнеп карады да гаҗәпләнүеннән өнсез калды, д'Артаньян исә әйләнеп карады да шатлыгыннан тынсыз калды.

— Әйе, нибары дүрт кенә тапкыр,— дип сөйләнде Атос,— бер тапкыр де Креки әфәнделәрдә; икенче тапкыр үземдә, үз замогымда идә... кыскасы, үземнең замогым бар чагында; өченче тапкыр де Тревиль әфәнделәрдә — безнең барыбызны да шаккатырган иде ул шунда; һәм соңгысы, дүртенче тапкыр бер мәйханәдә — шунда мин үзем ташлап йөз луидор акча белән аш мәҗлесе оттырган идем.

— Я, д'Артаньян әфәнде, атыгызны кире аласызмы? — дип сорады инглиз.

— Әлбәттә,— диде д'Артаньян.

— Димәк, мин кайтарышка уйный алмыйм.

— Без бит кайтарышка уйнамаска дип сөйләшкән идек, хәтерлисездер.

— Анысы дөрес, атыгыз хезмәтчегезгә тапшырылыр.

— Чак кына сабыр итегез әле,— диде Атос,— әфәндем, рөхсәт итсәгез, дустыма берничә генә сүз әйтер идем мин.

— Әйтегез, әйтегез.

Атос д'Артаньянны бер читкәрәк алып китте.

— Я, коткычы, тагын нәрсә телисең? Минем тагы да уйнавымны телисеңме? — диде д'Артаньян.

— Юк, мин сезнең бераз уйлап каравыгызны телим.

— Нәрсәне уйлап карыйм?

— Сез бит атыгызны кайтарып алырга телисез, шулаймы?

— Әлбәттә.

— Алай итеп ялгышасыз, мин, сезнең урында булсам, йөз пистоль акча алыр идем. Сезгә мәгълүмдер бит: сез иярге каршы ат яки йөз пистоль акча дип куйдыгыз — икесенең берсен?

— Әйе.

— Мин, мәсәлән, йөз пистоль акча алыр идем.

— Ә мин ат алам.

— Кабат әйтәм — алай итеп ялгышасыз. Икебезгә бер ат белән нишлибез без? Мин сезнең артка атлана алмыйм бит инде, ул чагында без Эмонның туганын югалткан ике малаена охшап калыр идек. Шулай ук сез минем яннан шундый шәп гаскәри ат өстендә барып мине рәнҗетә дә алмыйсыз. Мин уйлап та тормастан йөз пистоль акча алыр идем. Парижга кайтып житү өчен акча кирәк безгә.

— Ул ат миңа бик кадерле шул, Атос.

— Аның нәрсәсенә шаккатасың, дустым: ат абынып-сөртенеп аягын тайдыруы ихтимал, тез башларыннан йоны коелып

бетүе мөмкин, манка авырулы ат ашаган утлыктан ашавы бар, менә шулай итеп ат дигәнең, дөресрәге, йөз пистоль акчаң әрәм булды дигән сүз. Атның хуҗасы аны ашатырга-эчертергә тиеш, ә менә йөз пистоль акча, киресенчә, үзе хуҗасын ашата-эчертә.

— Өйгә ничек кайтып китәбез соң?

— Хезмәтчеләребез атына атланып, шайтан алгыры! Безнең килеш-кыяфәтебезгә карап та гади кеше түгеллегебез теләсә кемгә аңлашылырлык бит.

— Бер дигән чабышкыларына атланып алган Арамис белән Портос янында, бу ат сәләмәләренә атлангач, безнең килеш-кыяфәт бик тә шәп булыр инде!

— Арамис белән Портос янында! — дип Атос кычкырып әйтеп куйды да шаркылдап көләргә тотынды.

Д'Артаньян, дустының кәефе килү сәбәбен аңламыйча:

— Нигә көләсез? — дип сорады.

— Юк, болай гына, сүзне дәвам иттерик,— диде Атос.

— Сезнеңчә, димәк?..

— Йөз пистоль акча алырга кирәк, д'Артаньян. Йөз пистоль акчага без ай беткәнче типтереп яши алабыз. Без бик арыганбыз-йончыганбыз, шуңа күрә бераз ял итеп алсак, начар булмас иде.

— Ял итеп! Юк инде, Атос, мин Парижга кайтып җитү белән үк теге бичара хатынны эзләргә керешәм.

— Алай булгач — бигрәк тә! Әллә сез андый эштә атның да алтын тәңкә шикелле үк файдасы тияр дисезме? Йөз пистоль акча алыгыз, дустым, йөз пистоль акча алыгыз.

Д'Артаньянга, риза булу өчен, ышандырырлык тагын бер генә сүз җитми иде. Соңгы сүз аңа бик ышандыргыч булып тоелды. Өстәвенә, ул, һаман үз сүзен куәтләсә, Атос каршында эгоист булып күренүдән дә курыкты; шулай итеп, д'Артаньян, дусты әйткәнгә күнеп, йөз пистоль акча алырга булды. Инглиз шундук акчаны санап та бирде.

Хәзер инде безнең дусларның юл кайгысыннан башка кайгылары калмады. Трактир хуҗасы белән килешкәннән соң, Атосның карт атыннан тыш, тагын алты пистоль түләргә тиеш булдылар, д'Артаньян белән Атос Планше белән Гримо атларына атландылар, ә хезмәтчеләр, иярләрен баш өстенә күтәреп, җәяү киттеләр.

Атлары бик начар булса да, галиҗәнаплар хезмәтчеләрен бик тиз куып узып, Кревкерга алдан барып керделәр. Тәрәзә янында, офыкны каплаган тузан болытларына карап әкияттәге «Анна сенелкәш» шикелле, моңаеп утырган Арамисны алар ерактан ук күреп алдылар.

— Әй, Арамис! Нишләп сөрсеп ятасыз монда? — дип кычкырды ике дус.

— Ә, сезмени бу, д'Артаньян, сезмени бу, Атос,— диде егет,— мин әле менә бу дөнья рәхәтлекләренең фани булуы ту-

рында уйланып тора идем. Менә әле генә тузан болыты эченә китеп югалган минем инглиз аты минем өчен дөньяның фанилыгына теп-тере мисал булды. Безнең бөтен яшәешебезнең мәгънәсе өч сүзгә сыя: Erat, est, fuit *.

— Икенче төрле итеп әйтсәк? — диде д'Артаньян, эшнең хикмәтен сизенеп.

— Икенче төрле итеп әйтсәк, мине төпсез чуманга утырттылар. Йөрешенә караганда сәгатенә биш лье җир юргалап уза торган аргамагымны алтмыш луидор акчага биреп җибәрдем.

Д'Артаньян белән Атос эчләре катып көләргә тотындылар.

— Зинһар, ачуланмагыз мине, д'Артаньян дус, — диде Арамис, — беләсезме, мохтаҗлык бит ул бернинди закон белән дә исәпләшми. Өстәвенә иң күп зыян күрүче мин булдым, чөнки шул оятсыз барышник ким дигәндә илле луидор акчамны урлап калды. Менә сез, ичмасам, малның бәрәкәтен белә торган кешеләр! Үзегез хезмәтчеләрегез атына атлангансыз, ә үзегезнең бер дигән чабышкыларыгызны җайлап ял иттерә-ял иттерә, тезгеннәреннән җитәкләтеп кенә алып кайттырасыз.

Әлерәк кенә Амьен юлында күренгән ниндидер бер фургон шул минутта трактир янына килеп туктады да аннан, башларына ияр күтәреп, Планше белән Гримо төштеләр. Бу буш фургон Парижга кайтып бара, хезмәтчеләр юл хакы бәрабәренә олаучыларны юл буе эчертеп кайтырга килешкәннәр иде.

— Ничек ул алай? Иярләре генәмени? — дип гаҗәпләнде Арамис боларны күргәч.

— Төшендегезме инде? — диде Атос.

— Дуслар, сез дә нәкъ минем шикелле эшләгәнсез икән. Мин дә, ни өчендер, иярне үземә алып калдым. Әй, Базен! Минем яңа иярне алып бу галиҗәнапларныкы янына салыгыз.

— Ә сез изге аталар белән араны ничек өздегез соң? — дип сорады д'Артаньян.

— Икенче көнне мин аларны ашка чакырдым, — аш дигәннән, монда бик шәп шәраб бар, — шундый итеп эчерттем мин аларны — кюре миңа гаскәри мундирны салырга рөхсәт итмим, диде, ә иезуит миннән үзен мушкетерлыкка алулары хакында сөйләшүемне үтенде.

— Ләкин диссертациясез генә! Диссертациясез генә! Мин диссертациянең бетерелүен таләп итәм! — дип кычкырып әйтеп куйды д'Артаньян.

— Шуннан бирле минем тормыш ал да гөл, — диде Арамис. — Бер иҗекле сүзләр белән поэма язарга керештем. Шактый кыен эш ул, ләкин һәр эшнең төп кыйммәте дә аның кыенлыгында бит. Эчтәлеге мәхәббәт турында, мин сезгә аның беренче җырын укып күрсәтермен, дүрт йөз юллык булса да, укуы бер минутлык кына.

---

* Булыр, бар, булган.

Латин теле шикелле, шигырьне дә җене сөймәгән д'Артаньян:

— Беләсезме, Арамис дус, кыенлыгы дигән кыйммәте янына кыскалык дигән кыйммәт тә өстәсәгез, поэмагызның бер генә түгел, ике кыйммәте булачак,— диде.

— Аннан тыш, ул поэмадан саф кайнар тойгылар бөркелеп тора, менә үзегез дә тоярсыз әле. Димәк ки, дуслар, без Парижга кайтабыз? Браво! Мин әзермен! Чибәр егетебез Портосны да яңадан күрәбез — мин бик шатмын! Шул беркатлы Алып батырның никадәр юксынганымны белсәгез икән! Менә ул, тау чаклы алтын бирсәләр дә, атын сатмый инде. Өр-яңа иярле бер дигән чабышкысына атланып ничек кукраеп барганын тизрәк кайтып күрәсе иде. Бөек Моголга охшаячак ул, чын әгәр.

Дуслар, атларын ял иттереп, бер сәгатьлек привал ясадылар. Арамис трактир хуҗасы белән исәпне өзеп, Базенны фургонга иптәшләре янына утыртты да, барысы бергә Портос янына юлга кузгалдылар.

Портос хәзер сау-сәламәт иде инде, беренче тапкыр д'Артаньян килеп тапкандагы шикелле чырае да ап-ак түгел, ялгызы гына булса да дүрт кешелек аш хәзерләгән өстәл янында утыра иде; сыйлары бик шәп итеп әзерләнгән итле ашлардан, бер дигән шәраб һәм искиткеч яхшы җимешләрдән гыйбарәт иде.

— Хуш киләсез, әфәнделәрем,— диде Портос, урыныннан кузгалып,— бик вакытлы килеп кердегез, мин әле табынга утырган гына идем, бергәләп ашап-эчеп алырбыз.

— Оһо! Бу шешәләр теге, Мушкетон лассо белән чалдырып алган ише генә түгел бугай. Әнә бозау ите, әнә филе...— дип сөйләнде д'Артаньян.

— Мин хәл җыям, беләсезме, хәл җыям мин,— диде Портос.— Бу аяк тайдырудан да яман нәрсә юк икән: тәмам эштән чыгара. Атос, сезнең берәр тапкыр аяк тайдырганыгыз бармы?

— Юк, шулай да бер нәрсә хәтеремдә: Феру урамында сугышканда мине кылыч белән яралаганнар иде, шул яраланудан соң ике атна-ике атна ярым узгач, мин дә нәкъ сезнең кебек булдым.

— Бу аш мәҗлесе безнең өчен генә хәзерләнмәгән булса кирәк, Портос дус? — дип сорады Арамис.

— Әйе шул,— диде Портос,— мин шушы тирәдә яшәүче берничә дворянны көткән идем дә, алар әле яңа гына «киләлмыйбыз» дип хәбәр иттерделәр. Аларны сез алмаштырырсыз, андый алмашудан берниди зарар юк миңа. Әй, Мушкетон! Урындыклар китер, шешәләрне бермә-бер арттыр.

— Беләсезме, без нәрсә ашыйбыз? — дип сорады Атос берничә минуттан.

— Белмәскә! — диде д'Артаньян.— Мин үзем, мәсәлән, янына артишок белән җелек куелган, шпикланган бозау ите ашыйм.

— Ә мин — сарык филесе,— диде Портос.

— Ә мин — тавыкның түш итен,— диде Арамис.

Атос җитди бер төс белән боларга каршы төште:

— Ялгышасыз, әфәнделәр, сез ат ите ашыйсыз.

— Юкны сөйләмәгез әле! — диде д'Артаньян.

— Ат ите! — диде Арамис, җирәнгән итенеп.

Тик Портос кына бер сүз дә дәшмәде.

— Әйе, ат ите. Шулай бит, Портос, без ат ите ашыйбыз бит? Җитмәсә, ияре белән бергәдер әле?

— Юк, әфәнделәрем, дирбияләрен алып калдым,— диде Портос.

— Валлаһи, без барыбыз да бик әйбәт икәнбез. Сүз куешкан кебек,— диде Арамис.

— Нишләмәк кирәк? — диде Портос.— Ул атны күргәч, кунакларым уңайсызлана калдылар, минем инде аларны уңайсызлыйсым килмәде!

— Өстәвенә, герцогинягыз да әле һаман шифалы суда ята, шулаймы? — дип сорады д'Артаньян.

— Ята шул,— диде Портос.— Аннары, беләсезме, провинция губернаторы — бүген аш мәҗлесенә көткән олы кунакларымның берсе иде ул,— минем атны шул хәтле дә ошаткан — атны аңа биреп җибәрдем мин.

— Биреп җибәргән! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян.

— Ай алла! Әйе шул, биреп җибәрдем,— диде Портос,— чөнки аның чын бәһасы һичшиксез йөз илле луидор булса да, ул карунның мица сиксәннән артык бирәсе килмәде.

— Ияреннән башкамы? — дип сорады Арамис.

— Әйе, ияреннән башка.

— Сизәсезме, әфәнделәр: Портос һәрвакыттагыча безгә караганда отышлырак булып чыккан бит,— диде Атос.

Дусларның өчесе шаркылдашып көлеп җибәрделәр, бичара Портос бөтенләй уңайсызланып-аптырап калды, көлешүнең сәбәбен аңлатып биргәч инде Портос үзе дә, гадәтенчә, шаулап-гөрләп тегеләргә кушылды.

— Алайса без барыбыз да акчалы? — дип сорады д'Артаньян.

— Миннән башкаларыгыз,— диде Атос.— Арамистагы испан шәрабы бик ошап китте дә хезмәтчеләребез фургонына алтмышлап шешә төяргә куштым. Шулай итеп, минем янчык шактый җиңеләеп калды.

— Ә мин соң,— диде Арамис,— уйлап карагыз: соңгы су акчама хәтле Мондидье чиркәве белән Амьен монастырена бирдем һәм, кайбер кичектергесез бурычларымны түләүдән тыш, гыйбадәт кылырга сәдакалар бирдем. Ул гыйбадәтләрне, әфәнделәр, безнең исәнлеккә дип кылачаклар, һәм, ышанам, аларның безгә файдасы тими калмас.

— Ә минем тайган аяк? — диде Портос.— Сезнеңчә, аның

бернинди чыгымы булмаганмы? Мушкетонның ярасын әйтмим дә инде — шул яра аркасында миңа көненә икешәр тапкыр табип китертергә туры килде, өстәвенә әле, бу тинтәк Мушкетонның ярасы, имеш, фәкать аптекарьларга гына күрсәтә торган төшендә дигән булып, миннән икеләтә акча түләттеләр. Киләчәктә андый яра алудан сак бул, дип кисәтеп куйдым мин аны.

— Ярый алай булгач,— диде Атос; д'Артаньян һәм Арамис белән күзгә күз карашып алды,— күрәм: сез ул бичара егеткә, мәрхәмәтле галиҗәнапларча, рәхим-шәфкать күрсәткәнсез.

— Кыскасы, бөтен чыгымнарымны түләгәннән соң, минем тагын утыз экю чамасы акчам кала,— диде Портос.

— Ә минем ун пистоль чамасы,— диде Арамис.

— Сезнең белән чагыштырганда без черегән байлар булып чыгабыз бугай,— диде Атос.— Д'Артаньян, сезнең йөз пистоль акчагызның күпмесе исән?

— Йөз пистоль, имеш! Иң элек, аның иллесен мин сезгә бирдем.

— Шулаймыни?

— Шайтан алгыры!

— Ә, әйе, искә төште, бик дөрес.

— Алты пистолен трктирчыга түләдем.

— Хайван ул трактирчы! Нигә алты пистоль бирдегез сез аңа?

— Трактирчыга бир, дип үзегез әйттегез ич.

— Сез хаклы, артык юмарт шул мин. Кыскасы — күпме калды?

— Егерме биш пистоль,— диде д'Артаньян.

— Ә миндә,— диде Атос, кесәсеннән вак акча чыгара башлап.— Ә миндә...

— Сездә рәт калмаган...

— Чынлап, бик әз икән шул, уртак акчага кушарлык та калмаган.

— Хәзер инде исәплик — күпме акчабыз бар икән. Портос?

— Утыз экю.

— Арамис?

— Ун пистоль.

— Сездә, д'Артаньян?

— Егерме биш.

— Җәмгысы күпме була? — дип сорады Атос.

— Дүрт йөз җитмеш биш ливр! — диде д'Артаньян, Архимед кебек бик тиз санап.

— Парижга кайтканда безнең әле, иярләрне санамыйча дүрт йөз ливрдан артык акча кала,— диде Портос.

— Ә эскадрон атлары белән нишлибез? — дип сорады Арамис.

— Эшлибез аны! Хезмәтчеләребезнең дүрт атын ике галиҗонап атына әйләндерәбез дә жирәбә салабыз. Җәяүле булып

калучыбызның берсенә ярты атка дүрт йөз ливр акча бар, аннары, кесәләребезне әйләндереп селкәбез дә калган барлык акчаны д'Артаньянга бирәбез: кулы җиңел аның, шул акчаны ала да беренче очраган уен йортына акчалы уйнарга китә, менә шул.

— Әйдәгез утырышыйк, ашлар суына бит,— диде Портос.

Алдагы көн мәшәкатьләрен шул рәвешчә хәл итеп, дүрт дус әйбәтләп ашап-эчтеләр дә калган ашларын Мушкетон, Базен, Планше һәм Гримо әфәнделәргә бирделәр.

Парижга кайтып җитүенә д'Артаньянны де Тревиль әфәндедән килгән бер хат көтеп тора иде. Хатта д'Артаньянның үтенече кабул булганлыгы, король хәзрәтләре аны мушкетерлар сафына алырга рөхсәт иткәнлеге әйтелгән иде.

Д'Артаньянның күңелендә асраган бердәнбер хыялы мушкетерлыкка алыну булганлыктан (Бонасье ханымны эзләп табу теләген әйтеп тә тормыйбыз инде), ул, бик сөенеп, әле ярты сәгать кенә элек аерылышкан дуслары янына кире йөгерде һәм аларны кайгыга калган, бик нык борчуга төшкән бер хәлдә күрде. Алар Атос янына киңәшкә җыелганнар, хәлләре шактый җитдиләшеп киткән чакларда гел шулай итә торган иде алар.

Де Тревиль әфәнде әле яңа гына аларга хәбәр иттергән: король хәзрәтләре беренче майда сугыш хәрәкәтләре башларга исәп тотканлыктан, боларга хәзер үк бөтен гаскәри кирәк-яракларын юнәтергә кирәк икән.

Дүрт философ, тәмам аптырашта калып, бер-берсенә караштылар: де Тревиль әфәнде тәртип мәсьәләсендә шаяртырга яратмый иде шул.

— Ул гаскәри кирәк-яракның бәясе күпме булыр дип уйлыйсыз соң сез? — дип сорады д'Артаньян.

— Ай, эшләр шәптән түгел,— диде Арамис,— без, спартаннар шикелле бик юмартланып, әле генә санап карадык: һәркайсыбызга ким дигәндә мең ярымшар ливр акча кирәк.

— Мең ярымны дүрткә тапкырласаң, алты мең ливр була,— диде Атос.

— Минемчә, безнең һәркайсыбызга меңәр ливр булса... дөрес анысы, мин спартан булып түгел, стряпчий * кебек саныйм...— диде д'Артаньян.

«Стряпчий» сүзен ишеткәч, Портос җанлана төште.

— Менә нәрсә. Минем бер планым бар! — диде ул.

— Менә монысында инде ниндидер өмет бар. Аның каруы миндә план дигәннең әсәре дә юк,— диде Атос салкын гына.— Д'Артаньянга килгәндә исә, әфәнделәр, безнең сафка алыну шатлыгыннан акылын җуйган ул. Мең ливр, имеш! Әйтсәм әйтим: минем бер үземә генә дә ике мең ливр кирәк.

---

* Король сараенда хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүче кеше. *(Ред. искәрмәсе.)*

— Дүрт тапкыр икең — сигез була,— дип сүзгә кушылды Арамис та,— шулай итеп, безгә гаскәри кирәк-яракка сигез мең ливр акча кирәк булачак. Дөрес, безнең иярләребез бар инде.

Атос де Тревиль әфәндегә барып рәхмәт әйтим дип кузгалган д'Артаньянның чыгып киткәнен көтеп торды да:

— Аннан ары, дустыбызның бармагында елык-елык итеп торган бик шәп асылташ та бар бит әле,— диде.— Шайтаныммы! Д'Артаньян бик яхшы иптәш ул, бармагында шундый зур байлык йөрткәндә, үзенең дусларын кыен хәлдә калдырмас әле! — диде.

## XXIX

## ГАСКӘРИ КИРӘК-ЯРАК ЮНӘТҮ

Атаклы бай нәселдән чыккан мушкетер җәнапларына карагандa д'Артаньянга гвардияче буларак кирәк-ярак юнәтү җиңелрәк булса да, дүрт дус арасында иң нык борчуга төшкәне, әлбәттә, ул иде; укучы сизгәндер инде: безнең Гасконь егете сак һәм саран дип әйтерлек бер кеше булса да, шул ук вакытта (мондый каршылыкны ничек аңлатыргадыр?) мин-минлеген күрсәтергә тырышуда Портостан бер дә ким түгел иде. Хәер, мин-минлеккә кимчелек китермәү кайгысыннан тыш, д'Артаньянның бу вакытта икенче төрлерәк борчуы да бар иде. Бонасье ханымның язмышы хакында күпме генә сорашып-белешеп караса да, ул берни аныклый алмады. Де Тревиль әфәнде Бонасье ханымның югалуы турында королевага әйтте; королева да галантерейчының яшь хатыны кайда икәнлеген белми иде, аны эзли башларга вәгъдә итте, тик мондый коры вәгъдә генә д'Артаньянны тынычландыра алмады.

Атос, беркая чыкмыйча, үзенең бүлмәсендә ята; ул кирәк-ярак юнәтәм дип аягымны да атламыйм дигән бер карарга килгән иде.

— Безнең тагын ике атна вакытыбыз бар. Әнә шул ике атна бетүгә, мин бернәрсә дә таба алмасам, дөресрәге — ул нәрсәләр үзләре килеп мине тапмаса, мин, үз маңгаена пуля җибәрергә теләмәгән җүнле католик буларак, кардинал хәзрәтләренең дүрт гвардиячесе белән яисә сигез инглиз белән талашып сугыш чыгарам да берәрсе үземне үтергәнче сугышам: алар, күбәү булгач, мине үтерми калмаслар. Аннары инде кешеләр минем турыда король өчен корбан булды дип сөйләрләр, шулай булгач, мин гаскәри кирәк-ярак юнәтмичә дә үз бурычымны үтәгән булам,— дип сөйләнде ул дусларына.

Портос, кулларын артка куеп, башын чайкый-чайкый:

— Мин үз планымны тормышка ашырачакмын,— дип тәкрарлап, бүлмәдә арлы-бирле йөренде.

Арамис та чәч бөдрәләрен аннан-моннан гына тараштырган, чырае карангы, үзе бер сүз сөйләшми иде.

Әнә шундый шомлы галәмәтләр дүрт дусның зур кайгы-хәсрәткә батканлыгын әйтеп тора иде.

Үз нәүбәтләрендә хезмәтчеләре дә, Ипполитның гаскәри атлары кебек, хуҗаларының кайгылы язмышын уртаклаштылар. Мушкетон сохари кимерә, диндарлыкны яратучы Базен чиркәүдән чыкмый. Планше чебен саный, Гримо исә ташларны да елатырлык кызганыч бер кыяфәт белән бары тик көрсенә, авыр сулый — хуҗасы тавыш-өн чыгарырга рөхсәт итмәгәнлектән, ул шушындый гомуми ямансу хәлдә дә сөйләшергә батырчылык итми иде.

Шулай итеп, өч дус,— Атосның кирәк-ярак юнәтү өчен аягымны да атламыйм дип ант иткәнлеген әйтеп киткән идек инде,— өйләреннән иртүк чыгып китеп, соң гына кайтып керәләр. Алар, берәр кеше акча янчыгын төшереп калдырмаган микән дигән шикелле, аяк астындагы ташларга карана-карана, тиктомалга урамнарда йөриләр. Каршыларына очраган һәр кешене, һәр нәрсәне бик игътибар белән күздән кичерәләр — әйтерсең алар кемнеңдер эзенә төшәргә чамалыйлар. Ә берберсе белән очрашканда: «Я, ничек соң? Син дә берни тапмадыңмы?» — дигән кебек, өметсез бер төс белән карашып кына алалар иде.

Шулай да беренче булып үз планын корган һәм гел шуны гына уйлап йөргән Портос аны беренче булып тормышка ашырырга да керәште. Уйлаган эшен һәрвакыт җиренә җиткерә торган бер кеше иде шул безнең хөрмәтле Портос. Беркөнне д'Артаньян, Портосның Сен-Ле чиркәвенә таба киткәнлеген күреп, нәрсәдер буласын сизгән кебек, аның артыннан иярде. Изге йортка керер алдыннан Портос мыек очларын бөтергәләп, кыска чөй сакалын сыпыргалады — аның инде бу гадәте бик зур тәвәккәллеккә җыенуын белгертә иде. Д'Артаньян, дустының күзенә чалынмаска тырышып, аның артыннан керде. Портос таш баганага барып сөялде. Д'Артаньян да, тегенең күзенә күренмичә, шул ук баганага икенче ягыннан килеп сөялде.

Чиркәү эче тулы халык, изге атаның вәгазь укыган чагы иде. Шул хәлдән файдаланып, Портос андагы хатыннарны күзли башлады. Мушкетонның тырышлыгы белән мушкетерның өс-башы пөхтә генә, ыспай гына бер хәлгә китерелгән, аның күңелендәге кәефсезлеген сиздерерлек түгел иде; дөрес анысы: эшләпәсе бераз кыршылган кыршылуын, кауры да бераз уңган, укалары да тоныклана төшкән, челтәрләре дә бик нык җуелгән, шулай да чиркәү эчендәге ярым карангыда болары кеше күзенә чалынмый, шуңа күрә Портос шул ук чибәр Портос иде.

Д'Артаньян үзләре килеп сөялгән таш баганага иң якын утыргычтагы олы гына бер чибәр ханымга игътибар итте. Бу чибәр ханым башына кара эшләпә кигән, тәне инде бераз

саргая, беркадәр арыгая да башлаган, әмма үзе тәкәббер бер кыяфәт белән туры катып утырган иде. Портосның күз карашы шул ханымга туктала да аннары тагын чиркәү түренә таба юнәлә иде.

Ханым әледән-әле кызарынгалап китә, үз нәүбәтендә ул да җилбәзәк Портоска яшен уты шикелле елт кына иттереп күз атып ала, мушкетер егетнең исә карашы шул секундта ук чиркәү эченә күчеп, нидер эзләгән сыман анда айкала башлый. Кара эшләпәле ханымның егетнең бу кыланышына бик нык үртәлгәнлеге күренеп тора иде; ул иреннәрен тешләштергәли, борын очын угалый һәм бер дә урынында тик утыра алмый иде.

Бу хәлне күргәч, Портос тагын мыек очларын бөтергәләп җибәрде, тагын кыска чөй сакалын сыйпаштырып алды да клирос янындарак утырган чибәр генә ханымга ым каккалый башлады. Бу ханым чибәр булуы өстено бик бай да иде, күрәсең, чөнки аның артында бер негр малае басып тора (анысы ханымга гыйбадәт кылганда идәнгә тезләнер өчен мендәр күтәреп килгән), аннары тышына герб чигелгән кечерәк бер букча сыман нәрсә тоткан асрау кыз да бар (анысы шул букчага салып ханымга догалык алып килгән иде).

Кара эшләпәле ханым Портосның күз карашы кая таба юнәлгәнен күзәтә торгач, егетнең карашы гел әлеге негр малае белән асравын ияртеп килгән бәрхет мендәрле ханымга тукталуын чамалап алды.

Портос исә үз нәүбәтендә оста гына итеп хәйлә уены уйный: әле теге ханымга күз кыскан була, әле бармакларын авызына куя, әле үтергеч дәрәҗәдә матур итеп елмаеп ала, ә чынында бу елмаюы үзе ташлаган ханымны үтерә — бәгырен телгәли иде.

Ахырында әлеге ханым түзмәде — күкрәгенә сугып алды да «mea culpa» * дигән сыман, каты гына итеп «һм!» дип куйды, бөтен кеше, хәтта кызыл мендәрле ханым да аңа таба борылып карадылар. Портос үзен сынатмады: бөтенесен күреп-аңлап торса да, берни сизмәгәнгә салышты.

Кызыл мендәрле ханым чыннан да бик чибәр иде шул, кара эшләпәле ханымны ул тәмам пошаманга төшерде, бу хатын аның үзе өчен бик хәтәр бер көндәш булачагын төшенде; Портос та аны кара эшләпәле ханымнан күп өлеш чибәррәк дип тапты; д'Артаньянга исә ул таныш хатын булып чыкты: кызыл мендәрле ханымның егеткә Мёнгта, Каледа һәм Дуврда очраганы бар, теге, д'Артаньянны эзәрлекләүче, чигәсе җөйле ир кеше аны миледи дип атаган иде.

Д'Артаньян, кызыл мендәрле ханымны күздән яздырмыйча, Портосның әлеге әкәмәт кыланышларын күзәтә бирде: ул кара эшләпәле бу ханымны Аю урамындагы прокурор хатыны бу-

---

* Мин гаепле.

лырга тиеш дигән фикергә килде, Сен-Ле чиркәвенең ул урамнан әллә ни ерак булмавы да моны раслап тора иде.

Уйлана торгач, д'Артаньян тагын шунысына да төшенде. Портос прокурор хатыныннан Шантильида авырып яткан чагында акча мәсьәләсендә саранланганы өчен үч алырга да тырыша иде.

Д'Артаньян тагын шунысын да күрде: Портосның бу ишарәләренә каршы тегеләрнең берсе дә җавап кайтармый иде. Болар бары тик иллюзия, хыялый бер нәрсә генә иде, хәер, чын мәхәббәт, чын көнчелек өчен хыял һәм иллюзиядән башка чынлык юк та бит!

Вәгазь бетте. Прокурор хатыны изге сулы савытка таба атлап китте. Портос изге су янына алданрак барып җитте һәм савытка бармагын гына тыгасы урында бөтен кулын батырды. Прокурор хатыны, Портосны минем өчен тырыша инде бу, дип уйлап, елмаеп куйды, тик ханым алай уйлап бик нык алданасын белмәде: Портос белән аралары ике-өч адым чамасы гына калгач, Портос ханымга арты белән борылды да күзен кызыл мендәрле ханымга төбәде: ул ханым да, урыныннан торып, негр малае һәм асравы белән бергә, бирегә таба килә иде.

Кызыл мендәрле ханым Портос янына килеп җиткәч, мушкетер егет изге суга манчылган кулын савыттан чыгарды; гыйбадәт кылырга килгән гүзәл ханым нәфис кулын Портосның көрәк чаклы кулына тидереп алып, елмаеп куйды, аннары чукынды да чиркәүдән чыгып китте.

Прокурор хатыны, билгеле инде, болай ук булыр дип көтмәгән иде; әлеге хатын белән Портос арасында гыйшык мөнәсәбәте барлыгына аның бөртек тә шиге калмады. Әгәр ул атаклы бер бай ханым булса, хәтта һушыннан да язган булыр иде, ләкин ул нибары прокурор хатыны гына иде шул, шуңа күрә ачуын-ярсуын тыеп, мушкетерга:

— Аһ, алаймыни, Портос әфәнде! Димәк, хәзер сез миңа изге су тәкъдим итмисез? — дип кенә әйтә алды.

Портос, аның тавышын ишеткәч, йөз еллык йокысыннан уянып киткән бер кеше кебек, дерт итеп сискәнеп куйды.

— Ха... ханым! — дип кычкыра төшеп әйтте ул.— Сезмени бу? Хәләл җефетегез хөрмәтле Кокнар әфәнденең кәеф-сафалары ничек? Элекке шикелле, һаман да саранмы? Күзем кайда булган икән соң минем? Ике сәгать буе вәгазь тыңлаганда ничек күрмәгәнмен мин сезне?

— Яныгызда гына идем, әфәндем, сез мине күрмәдегез шул, чөнки минә әле генә үзегез изге су тәкъдим иткән чибәр ханымнан күзегезне алмадыгыз,— дип җавап кайтарды прокурор хатыны.

Портос уңайсызланган булды.

— Алаймыни, сез күреп тордыгызмыни?..— диде.

— Шуны да күрмәскә — сукыр булырга кирәк.

— Әйе шул,— дигән булды Портос исе китмәгән шикелле генә,— бер герцогиня иде ул, минем дус хатын. Ире бик көнче, шуның аркасында рәтләп күрешә дә алмыйбыз. Менә әле бүген фәкать минем белән күрешер өчен генә шушы чиркәү аламасына, шушы аю оясына киләчәген белгерткән иде.

— Портос әфәнде, бер биш минутка гына кулыгызны бирмәссезме миңа? Сезнең белән бераз сөйләшәсе сүзем бар иде,— диде прокурор хатыны.

— Бик ризамын, ханым,— диде Портос, хәйлә корып мыек астыннан гына елмайган уенчы кебек, ханымга сиздермичә генә күз кысты.

Шул вакытны миледи артыннан ияргән д'Артаньян алар яныннан узып китте; Портоска борылып карагач, аның җиңүчән бер күз карашын күрде. Эченнән генә: «Әһә! Кем дигәндә дә Портосның, һичшиксез, тиешле вакытына гаскәри кирәк-яраклары булачак!» — дип уйлады. Егетнең мондый нәтиҗәсе җиңел акыллы ул заманга хас гаҗәп җиңел гадәт-йолалар рухына бик туры килә иде.

Портос, рульгә буйсынган көймә кебек, прокурор хатынының кулы белән кыскалавына буйсынып, Сен-Маглуар монастыреның ишегалдына килеп җитте. Ике башыннан да турникетлар * белән бүлеп алынган аулак бер урын иде бу. Көндез бу тирәдә нидер чәйнәп йөрүче хәерчеләр һәм уйнаган бала-чага гына күзгә чалынгалый иде.

Прокурор хатыны, бу аулак почмакның даими кешеләреннән башка үзләрен беркем күрмәячәк һәм ишетмәячәк икәнлегенә ышангач, кычкыра төшеп әйтә куйды:

— Аһ, Портос әфәнде! Аһ, Портос әфәнде, сез коточкыч бер мут кеше булсагыз кирәк! — диде.

— Минме, ханым? — диде Портос, түшен киерә төшеп.— Нигә алай дип уйлыйсыз әле сез?

— Әле генә сез ясаган ишарәләр, изге су соң? Негр малае белән асравын иярткән ханым нинди кеше ул? Ким дигәндә дә бер принцессадыр!

— Хаталанасыз, бер герцогиня гына ул,— диде Портос.

— Ә ул ханымны ишек төбендә көтеп торган җәяүле озатучысы, аннары карета, карета башында укалы киемнән ханымны көтеп торган кучер?

Портос ул ханымның лакеен да, каретасын да абайламаган иде, ә менә Кокнар ханым көнчел күзләре белән барысын да күреп калган икән.

Портос кызыл мендәрле шул ханымны башта ук принцесса итмәвенә үкенеп куйды.

— Аһ, Портос әфәнде, чибәр хатыннар узындырып бетергән икән үзегезне,— дип авыр сулап куйды ханым.

* Әйләнмәле капка.

— Үзегез дә аңлыйсыздыр: табигать биргән шундый чибәрлегем барында мәхәббәт мажараларына мохтаҗлыгым юк минем,— диде Портос.

Прокурор хатыны, күзен гарешкә төбәп, кычкыра төшеп әйтә куйды:

— И ходаем! Ник бу кадәр тиз оныталар икән ирләр!

— Шулай да хатыннар кебек үк түгел инде,— диде Портос.— Менә мин — бер дә икеләнмичә әйтә алам — мин сезнең корбаныгыз булдым, ханым: яраланып үлем хәлендә яткан чагымда яныма табиплар да килмәде; мин, атаклы бай нәселдән чыккан бер кеше, сезнең дуслыкка ышанып, башта яраларымнан, аннары Шантильидагы хәерче бер кунакханәдә ачтан чак үлми калдым, шул вакытта сез минем ялкынлы хатларымның берсенә дә җавап бирмәдегез.

— Карагыз әле, Портос әфәнде...— дип кенә мыгырданып куйды прокурор хатыны, андый вакытта атаклы бай ханымнарның үзләрен ничек тотулары белән чагыштырып карагач, үзенең чыннан да гаепле булуын тойды.

— Мин сезнең хакка баронесса де... не корбан иттем,— диде Портос.

— Анысын беләм.

— Графиня де... не.

— Һай, Портос әфәнде, кызганыгыз исмасам мине!

— Герцогиня де... не.

— Портос әфәнде, миһербанлы булыгыз инде.

— Яхшы, ханым, мин бүтән әйтмим.

— Әҗәткә акча бирү турында ирем ишетергә дә теләми бит.

— Кокнар ханым, миңа язган беренче хатыгызны хәтерегезгә төшерегез әле. Ул хат мәңгелеккә минем бәгыремә уелып калды.

Прокурор хатыны тирән итеп көрсенеп куйды.

— Сез бурычка дип сораган акча, дөрестән дә, бик зур сумма бит.

— Кокнар ханым, башкаларга караганда мин сезгә күбрәк ышанган идем. Әгәр мин герцогиня де... гә язган булсам. Мин аның исемен атап әйтмим, чөнки мин һәрвакыт хатын-кызның абруе турында уйлыйм; кыскасы, мин хат язу белән үк мең ярымны җибәрә иде ул.

Прокурор хатыны елый ук башлады.

— Портос әфәнде, ант әгәр, минем өчен ходайның каты җәзасы булды бу, киләчәктә андый хәлгә төшсәгез — миңа гына мөрәҗәгать итегез.

— Шулай дию ничек оят түгел сезгә, ханым! — диде Портос нәфрәтләнгән булып.— Зинһар, акча турында бүтән сөйләшмик, кешенең дәрәҗәсен төшерә ул.

Прокурор хатыны кайгылы бер төс белән әкрен генә сөйләнеп куйды:

— Димәк, сез минe бүтән яратмыйсыз инде?

Портос ләм-мим дәшмәде.

— Бу сезнең җавабыгыз инде, ни дигәнегезне аңлыйм.

— Мине ничек мыскыл иткәнлегегезне исегезгә төшерегез, ханым; менә монда утыра ул,— диде Портос, кулын күкрәгенә кысып.

— Ышаныгыз, сөекле Портос, опыттырырмын мин аны!

— Нәрсә сорадым мин сездән? — диде Портос чын-ихлас күңелдән җилкәсен сикерткән булып.— Бурычка, нибары бурычка акча гына сорадым бит. Мин бит акылсыз кеше түгел, сезнең бай булмавыгызны, ирегез ярлы дәгъвачыларыннан барлы-юклы соңгы экюларын сыгып алганлыгын беләм мин, Кокнар ханым. Әгәр дә сез графиня, маркиза яки герцогиня булсагыз икән әле, ул чагында башка хәл булыр иде, о, ул чагында сезнең андый гамәлегезне һич гафу итеп булмас иде.

Прокурор хатынының хәтере калды.

— Шуны белеп торыгыз, Портос әфәнде,— диде ул,— минем сандыгымда, прокурор хатыны гына булсам да, сезнең бөлеп беткән сөяркәләрегезнең барысыныкына караганда да акчам күбрәктер, бәлкем.

— Ул чагында инде, Кокнар ханым, сез икеләтә мыскыл иткәнсез мине,— диде Портос, кулын прокурор хатынының кулыннан ычкындырып,— чөнки сез бай булсагыз, минем үтенечемне кире кагуыгызны берничек тә аклап булмый.

— «Бай» дигәч тә мин әйткәнне сүзгә-сүз аңларга кирәкми лә,— диде прокурор хатыны, артыграк ычкындырганлыгын абайлап.— Мин бигүк бай булмасам да, ул кадәр генә акчам бар әле.

— Менә нәрсә, ханым, зинһар, бу сүзне туктатыйк. Сез инде миннән ваз кичкәнсез! Безнең арада берниндн дуслык калмаган,— диде Портос.

— Ит яхшылык — көт явызлык!

— Аһ, сез әле миннән риза түгел икәнсез! — диде Портос.

— Әнә теге гүзәл герцогинягыз янына барыгыз. Мин сезне тотмыйм.

— Ярый алайса! Бик сөйкемле хатын ул, минемчә.

— Соңгы тапкыр сүземә җавап бирегез әле, Портос әфәнде,— сез мине әле хәзер дә сөясезме?

— Ай, ханым,— диде Портос, булдыра алган кадәр тавышына кайгылы төс бирергә тырышып,— озакламый без походка чыгабыз, күңелем сизә: мин анда үлеп калачакмын...

Прокурор хатыны:

— Ай, андый сүзләр сөйләмәгезче! — диде дә үкереп еларга ук кереште.

— Күңелем шулай сизә,— диде Портос тагы да кайгыга сабыша төшеп.

— Сез инде, ичмасам, әйтегез: яңа гыйшык утында янам, диегез.

— Юк, юк, ихластыр... Бернинди дә яңалар кызыксындырмый мине, киресенчә, менә монда, йөрәк түремдә, әле һаман да сезгә карата хисем барлыгын тоям. Әмма, сезгә мәгълүмдерме, түгелдерме,— ике атнадан без әлеге әҗәл походына чыгып китәчәкбез, һәм мин бик нык ыгытып гаскәри кирәк-яраклар юнәтү мәшәкате белән мәшгуль булачакмын, шуңа җитәрлек акча табу өчен туганнарым янына, Бретань төбәгенә кайтып килергә туры килә инде миңа.

Портос мәхәббәт белән саранлык арасында соңгы тартыш барганлыгын сизеп калды.

— Сез әле чиркәүдә күргән герцогиняның утары минеке белән янәшә генә, шуңа күрә без аның белән бергә кайтып китәбез, үзегез беләсез инде, янында юлдашың булганда юлның узганы сизелми дә кала,— дигән булды Портос.

— Димәк, сезнең Парижда дусларыгыз юк, Портос әфәнде?— дип сорады прокурор хатыны.

— Дусларым бар дип уйлаган идем дә ялгышкан икәнмен,— диде Портос, янә чыраена кайгылы төс чыгарып.

— Портос әфәнде, дусларыгыз бар сезнең, бар, бик бар! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды прокурор хатыны, аның болай кинәттән җилкенеп куюы үзенә дә бик гаҗәп тоелды.— Иртәгә килеп чыгыгыз безгә. Сез — минем апаемның улы булырсыз, димәк, минем туганнан туган энем буласыз. Сез Пикардия ягыннан, Нуайоннан килгәнсез. Сезнең Парижда суд аша хәл итәсе берничә дәгъвалы эшегез бар, ләкин стряпчиегыз * юк. Хәтерләп калдыгызмы?

— Бик яхшы хәтерләп калдым, ханым.

— Төшке ашка килеп чыгыгыз.

— Бик яхшы.

— Тик карагыз аны — ялгыш сүз ычкындыра күрмәгез: минем ирем җитмеш алты яшендә булса да, бик сизгер.

— Җитмеш алты яшь! Шайтан алгыры! Яше бик әйбәт бит! — дип куйды Портос.

— «Яше бик олы!» — дип әйтмәкче буласызмы? Әйе шул, Портос әфәнде, ирем, бичара, бүген-иртәгә мине тол калдыруы да ихтимал,— дип сөйләнде прокурор хатыны. Портоска мәгънәле генә күз салгалап.— Бәхеткә каршы, безнең никах килешүе буенча бөтен мал-мөлкәт, беребез үлгәч, икенчебезгә кала.

— Бөтенләе беләнме? — дип сорады Портос.

— Бөтенләе белән.

— Күрүемчә, бик хәстәрле хатын икәнсез, сөекле Кокнар ханым,— диде Портос, прокурор хатынының кулын яратып кысып.

— Алайса без татулаштык, әйеме, сөекле Портос әфәнде?— диде ханым чытлыкланып.

— Гомерлеккә! — диде Портос та шул ук рухта.

---

* Биредә суд эшендә булышлык итүче мәгънәсендә. *(Ред. искәрмәсе.)*

— Ярый, сау бул, хыянәтчем!
— Хуш, җилбәзәгем.
— Иртәгә күрешербез, фәрештәм.
— Күрешербез, якты йолдызым.

## XXX

## МИЛЕДИ

Д'Артаньян, сиздермәскә тырышып кына, миледи артыннан иярде; ул аның каретага утырганын күреп, кучерга Сен-Жерменга барырга кушуын ишетеп торды.

Таза пар ат җиккән карета артыннан җәяүләп кенә ияреп барырга тырышу мәгънәсез бер эш булыр иде. Шуңа күрә д'Артаньян Феру урамына китте.

Сена урамында аңа Планше очрады; Планше бер кондитер кибете витринасы каршында күпереп пешкән бик тәмле күмәчкә кызыгып карап тора иде.

Д'Артаньян аңа де Тревиль әфәнде абзарыннан — берсе аның өчен, икенчесе Планшеның үзе өчен — ике ат алып иярләргә дә шуннан үзе янына Атос квартирына килергә кушты. Де Тревиль әфәнде д'Артаньянга үз атларыннан теләгән чакта файдаланырга рөхсәт иткән иде.

Планше Иске Күгәрчен оясы урамына, д'Артаньян исә Феру урамына китте. Ул килеп кергәндә Атос өендә иде, күңелсез генә бер кыяфәттә, Пикардиядән алып кайткан бик шәп испан шәрабы эчеп утыра иде. Ул Гримога ишарәләп кенә д'Артаньян өчен дә стакан китерергә кушты, Гримо, гадәтенчә бер сүз әйтмәстән, кушканны үтәргә китте.

Д'Артаньян Атоска чиркәүдә Портос белән прокурор хатыны арасында булган хәлләрне сөйләп бирде һәм, иптәшебез гаскәри кирәк-яракны юнәтү юлына төшкән булырга тиеш, дигән фаразын әйтте.

— Миңа килгәндә, минем җаным тыныч: әлбәттә, минем кирәк-яраклар чыгымын хатын-кызлар үз өсләренә алмаячак,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Хәлбуки, Атос дус, сезнең чибәрлегегез, яхшы тәрбияле һәм атаклы бай нәселдән булуыгыз теләсә кайсы принцесса яки королеваның йөрәген Амур угы белән яралар иде.

— Бик яшь шул әле бу, д'Артаньян! — диде Атос, җилкәсен сикертеп, һәм Гримога ишарәләп кенә тагын бер шешә китерергә кушты.

Шул вакытны яртылаш ачык ишектән әкрен генә башын сузып Планше карады һәм хуҗа әфәндесенә атлар әзер икәнлеген әйтте.

— Нинди атлар ул? — дип сорады Атос.

— Де Тревиль әфәнде миңа йөреп кайтыр өчен ике ат биреп торган иде. Сен-Жерменга барып кайтырга җыенам әле.

— Нишләмәкче буласыз анда, Сен-Жерменда? — дип сораша бирде Атос.

Шуннан д'Артаньян аңа чиркәүдә бер ханымны очратуын һәм, чигәсендә яра эзе булган кара плащлы кеше кебек үк һаман уеңда йөргән әлеге хатынны янадан ничек табуын сөйләп бирде.

— Икенче төрле итеп әйткәндә, әлегрәк Бонасье ханымга гашыйк булган кебек, бу хатынга да гашыйк булгансыз,— диде Атос, адәм баласының андый йомшак яклары була шул, дигән сыман, яхшысынмаган кебек җилкәсен сикертеп куйды.

— Минме?! Һич алай түгел! — диде д'Артаньян кычкыра төшеп.— Минем бары тик шул хатын белән бәйләнешле әлеге серне генә ачасым килә. Ни сәбәптәндер миңа бөтенләй билгеле булмаган шул хатынның,— ул да мине белми,— минем тормышыма ниндидер йогынтысы бар кебек.

— Асылда, сез хаклы,— диде Атос,— хатын-кыз югалган икән, аны эзләп йөрисе юк. Мин дөньяда югалгач эзләп табылырга тиешле хатын-кыз барлыгын белмим. Бонасье ханым юкка чыккан икән — аның үзе өчен генә начар, югалгач үзе табылсын.

— Юк, Атос, сез дөрес сөйләмисез,— диде д'Артаньян дустының бу сүзенә каршы.— Мин ул бичара Констанциямне элеккедән дә катырак яратам, мин аның кайда икәнлеген белсәм, җир читендә булса да, барып, дошманнары кулыннан йолып алыр идем, тик кайда икәнлеген генә белмим,— эзләп-эзләп тә мәгънә чыкмады. Нишләмәк кирәк! Күңелгә бераз юаныч эзләргә туры килә.

— Ярый, ярый, миледи белән юаныгыз инде алайса, д'Артаньян дус, әгәр шул сезгә юаныч була торган булса, ихлас күңелемнән телим аны.

— Карагыз әле, Атос,— диде д'Артаньян,— тоткынлыктагы шикелле өйдә бикләнеп утырганчы, әйдәгез атка атланыгыз да икәүләп Сен-Жерменга барып кайтабыз.

— Дустым, мин атым барында гына атланам атка, атым югында җәяү йөрим,— диде Атос бу тәкъдимгә каршы.

— Ә мин сезнең кебек алай артык горур түгел, нинди туры килсә, шуңа атланам,— диде д'Артаньян, үз фикере белән Атосның санашмавына елмаеп кына куйды, башка вакытны башка мәсьәләдә булса, һичшиксез, моңа кәефе китәр иде.— Алайса, сау булып тор, Атос дус.

— Сау бул,— диде мушкетер, Гримога ишарәләп кенә яңа шешәне ачарга кушты.

Д'Артаньян белән Планше, атларына атланып, Сен-Жерменга китеп бардылар.

Атосның Бонасье ханым турында әйткәне юл буе д'Артаньянның башыннан чыкмады. Егет артык нечкә күңелле булмаса да, галантерейчының сөйкемле, чибәр хатыны аның йөрәгендә тирән эз калдырган иде шул: Бонасье ханымны эзләп та-

бар өчен ул чыннан да җир читенә китәргә дә әзер, ләкин җир түгәрәк, аның чит-чоты бик күп, шуңа күрә ул кай тарафка китеп барырга да белми иде.

Ә хәзергә егет әлеге милединың ниндирәк кеше икәнлеген белергә тырышып карамакчы булды. Милединың теге кара плащлы кеше белән сөйләшкәне бар — димәк, ул аны белә. Хәлбуки, д'Артаньянның күңелендә Бонасье ханымны, беренче тапкырындагы кебек үк, икенче тапкыр да шул кара плащлы кеше урлаган дигән фикер туды. Шулай итеп, д'Артаньян, миледины эзләү шул ук вакытта Констанцияне дә эзләү ул, дип яртылаш кына алдаша, ә яртылаш кына алдашу ул бөтенләй алдашу дигән сүз түгел әле.

Шуларны уйлап, ара-тирә атын шпорлап чаптыра торгач, д'Артаньян үзе дә сизмәстән тиешле араны узып, Сен-Жерменга килеп җитте. Ул елдан соң Людовик XIV нче туасы павильон янышнан үтеп, егет буш урам буйлап китте, гүзәл инглиз хатынының берәр эзен табарга өметләнеп уңга-сулга каранды һәм шунда кинәт ул замандагы тәртип буенча урам ягында бер тәрәзәсе дә булмаган матур гына йортның аскы катына терәлеп торган, чәчәкләр белән бизәлгән террасада арлы-бирле йөренгән таныш гәүдә күзенә чалынды. Иң элек Планше танып алды аны.

— Әфәндем, теге кешенең кыяфәте танышмы сезгә? Әнә авызын ачып безгә карап торган кешенең? — диде ул.

— Юк, таныш түгел, шулай да аны беренче тапкыр күрүем түгелдер дип беләм,— диле д'Артаньян.

— Әлбәттә! — диде Планше.— Теге бичара Любен бит ул, граф де Вардның лакее, моннан бер ай элек Каледа, порт башлыгы янына барганда, сез ул графны бик әйбәтләп эшкәртеп ташлаган идегез.

— Әйе, әйе, хәзер мин дә таныдым,— диде д'Артаньян.— Ә син ничек уйлыйсың: сине танырмы ул?

— Дөресен әйткәндә, әфәндем, шул хәтле дә коты алынган иде аның — мине алай ачык хәтерләп калырлык хәлдә булдымы икән.

— Алайса, син ул егет янына бар да сүз кушып кара. Аның графы исән микән, түгел микән — сүз арасында гына шуны белергә тырыш,— диде д'Артаньян.

Планше, атыннан төшеп, туп-туры Любен янына китте. Графның лакее чыннан да аны танымады, шуннан соң ике хезмәтче, бик тиз уртак тел табып, сөйләшеп киттеләр; ул арада д'Артаньян атларны тыкрыкка алып кереп китте дә йортны әйләнеп узып, тегеләрнең әңгәмәсен тыңлап тору нияте белән, чикләвек куаклары ышыгына посты.

Киртә артыннан бераз күзәтеп торганнан соң, ул көпчәк тавышы ишетте, һәм егетнең каршысына гына теге миледи каретасы килеп туктады. Тәгаен, каретаның эчендә миледи үзе

утыра иде. Д'Артаньян, үзе күренмичә, бөтенесен күреп тору өчен, иелеп, атының муенына сыенды.

Аксыл-сары чәчле чибәр миледи карета тәрәзәсеннән башын чыгарды да асравынаниндидер йомыш кушты.

Асравы — егерме-егерме ике яшьләрендәге теречә, җитез бер кыз, атаклы бай ханымның чын субреткасы * — карета күтәрмәсеннән сикереп төште дә (ул заманда асраулар карета күтәрмәсенә утырып йөргәннәр) Любен басып торган террасага таба китте.

Д'Артаньян субретканың кая барганын карап торды — кыз террасага таба бара иде. Ләкин моннан бер минут алдарак кына эчтән кемдер Любенны чакырып алган, террасада Планше гына калган — ул, хуҗасының кая юкка чыкканлыгын чамаларга тырышып, як-ягына карангалап тора иде.

Асрау кыз Планше янына килде дә, аны Любен дип белеп, язу сузды.

— Сезнең хуҗа әфәндегезгә тапшырасы,— диде кыз.

— Минем хуҗа әфәндемә? — дип гаҗәпләнеп кайтарып сорады Планше.

— Әйе, бик ашыгыч эш буенча. Алыгыз инде.

Шулай дигәч, кыз каретага йөгерде. Карета инде кире якка борылып куйган иде, кыз күтәрмәгә сикереп менүгә — китеп тә барды.

Планше язуны тегеләй-болай әйләндергәләп карады, аннары кушканны берсүзсез үтәү гадәте буенча, террасадан сикереп төште дә тыкрыкка кереп китте, егерме адымнар чамасы баргач, д'Артаньянны очратты — хуҗа әфәндесе хәлне күреп торган, хәзер ул үзе Планшега каршы килә иде.

— Мәгез, сезгә бу, әфәндем,— диде Планше, язуны егеткә сузып.

— Миңа? Чынлапмы? — дип сорады д'Артаньян.

— Чынлаптырмы, түгелдерме — шайтан белгән! Асрау кыз әйтте: «Синең хуҗа әфәндеңә тапшырасы»,— диде. Минем инде сездән башка хуҗа әфәндем юк, шулай булгач... Асравы, һай, бик чибәр кыз икән!

Д'Артаньян хатны ачып, мондый сүзләрне укыды:

«Сезнең белән бик кызыксынганын теле белән әйтеп бирә алмаучы бер ханым сезнең кайчан урманда йөреп кайта алачагыгызны белергә тели. Иртәгә «Алтын басу» кунакханәсендә каралы-кызыллы кием кигән лакей сездән җавап көтәчәк».

«Оһо! Туры килүен күр әле син! Мин дә, миледи да бер үк кешенең сәламәтлеге белән кызыксынабыз бугай»,— дип уйлап куйды д'Артаньян.

---

* **Субретка** — асрау кыз.

— Әй, Планше! Де Вард әфәндедең хәле ничек соң? Сизүемчә, үлмәгән бугай әле ул?

— Юк, әфәндем, ярасына күрә хәле әйбәт икән. Гаеп итеп әйтүем түгел: сез бит ул чибәр егеткә кылыч белән дүрт тапкыр кададыгыз, шуңа күрә әле ул бик хәлсез икән, чөнки бик күп каны аккан булган. Нәкъ мин уйлаганча, әфәндем, Любен мине танымады, безнең теге мажараны башыннан ахырына хәтле сөйләп бирде.

— Бик шәп, Планше, лакейларның короле син. Ә хәзер әйдә атына атлан да карета артыннан куып житик.

Моның өчен әллә ни күп вакыт кирәк булмады; бер биш минуттан алар юл читендә туктап калган каретаны күрделәр; карета ишеге янында зат киемле бер жайдак атын кыбырсытып тора иде.

Миледи белән әлеге жайдак бик мавыгып гәпләшеп торалар иде, д'Артаньян аты белән каретаның икенче ягына килеп туктагач та, аңа баягы чибәр субреткадан башка игътибар итүче булмады.

Тегеләр д'Артаньян белмәгән инглиз телендә сөйләшәләр иде, шулай да егет гүзәл инглиз хатынының бик нык ачуы килгәнлеген тавышыннан ук сизде, ханымның соңгы жесты исә аларның нинди рухта сөйләшкәнлекләренә бернинди шик-шөбһә калдырмады: миледи кулындагы жилпәзәсен шундый бер ачу белән тетрәнеп кысты — жилпәзә челпәрәмә килеп уалып төште.

Атлы жайдак бу хәлгә шаркылдап көлеп кенә жибәрде, аның көлүе исә милединың тагы да ачуын гына китерде шикелле.

Д'Артаньян боларның арасына керергә вакыт житте дип уйлады, аты белән икенче ишек янына килде дә ихтирам күрсәтеп башыннан эшләпәсен салды.

— Ханым, сезгә ярдәм күрсәтергә рөхсәт итегез. Күрүемчә, бу атлы жайдак сезнең ачуыгызны бик нык китерде шикелле. Бер генә сүз әйтегез — мин аңа әдәп сакламаганы өчен жәза бирергә керешәм,— диде егет.

Д'Артаньян сөйли башлау белән үк миледи гажәпсенеп аңа таба борылып карады. Егет сүзен әйтеп бетергәч, чибәр ханым саф французча итеп:

— Әфәндем, минем белән бәхәс кылучы бу кеше туганым булмаса, мин сезнең ярдәмегезгә сыенырга бик риза булыр идем.— диде.

— О, ул чагында гафу итегез мине,— диде д'Артаньян.— Мин моны белмәгәнмен, ханым.

Миледи туганым дип атаган атлы жайдак, карета ишегенә таба иелә төшеп:

— Нигә әле бу жилкуар — кеше эшенә килеп тыкшына? Нигә ул үз юлы белән генә китеп бармый? — дип кычкырды.

Д'Артаньян да, карета ишеге янында торган килеш, үз нәүбәтендә атының муенына иелә төшеп:

— Сез үзегез җилкуар! Миңа шушында туктарга кирәк иде, шуңа күрә үз юлым белән китмәдем,— дип җавап кайтарды.

Атлы җайдак үзенең сеңлесенә инглизчә берничә сүз әйтте.

— Мин сезнең белән французча сөйләшәм, рәхим итеп миңа да француз телендә җавап бирегез. Сез бу ханымның абыйсы икәнсез, бик яхшы, шулай булсын, тик, бәхеткә каршы, сез минем туганым түгелсез,— диде д'Артаньян.

Болар арасында ызгыш-талаш чыгып, зурга китмәсен өчен, миледи, хатын-кызларча андый хәлдән куркып, арага керер дип кӧтелсә дә, алай итмәде — киресенчә, гәүдәсен карета эченә алып, җайлабрак утырды да кучерына тыныч кына итеп:

— Өйгә киттек,— диде.

Сөйкемле, чибәр субретка д'Артаньянга борчулы бер караш ташлап алды: егетнең чибәрлеге аңа тәэсир итми калмады, күрәсең.

Карета, кара-каршы басып торган ике ирне шул урыннарында калдырып, китеп барды: хәзер инде болар арасында берниндн киртә юк иде.

Атлы җайдак карета артыннан китмәкче булып кузгала башлауга, д'Артаньян аны тезгененнән тартып кире туктатты: бу кешенең Амьенда чакта д'Артаньянның атын откан, Атостан асылташны ота язган инглиз икәнлеген танытач, егетнең ачуы отыры кузгалган иде.

— Әй, әфәндем, сез әле миннән дә битрәк җилбәзәк бугай: безнең арада беркадәр низаг башланып калганлыгын онытмадыгызмы әле? — диде аңа д'Артаньян.

— Аһ, сезмени бу, әфәндем,— диде инглиз.— Сез уеннан бер дә туктап тормыйсыз, күрәмсең,— бер уен булмаса, икенчесен уйныйсызмы?

— Әйе шул, менә әле минем әҗәт кайтарасым барлыгын исемә төшердегез. Карап карарбыз, дустым: рапира белән дә шакмак белән эш иткән шикелле оста эш итәсез микән?

— Сез минем янымда кылычым юклыгын бик яхшы күреп торасыз. Әллә сезнең коралсыз кеше каршында батырлыгыгызны күрсәтәсегез киләме? — диде инглиз.

— Өегездә кылычыгыз бардыр дип уйлыйм,— диде моңа каршы д'Артаньян.— Ихтыярыгыз, минем кылычым икәү, теләсәгез, берсен оттырам сезгә.

— Анысы артык булыр, миндә андый әйберләр житәрлек,— диде инглиз.

— Алайса, бик яхшы, хөрмәтле кавалер! — диде д'Артаньян.— Шулар арасыннан иң озынын сайлап алыгыз да бүгенкич миңа күрсәтерсез.

— Сез аны кай төштәрәк күрергә телисез инде?

— Люксембург сарае артында. Андый уен өчен бик шәп урын ул.

— Яхшы, килермен.

— Кайчанрак?

— Сәгать алтыда.

— Хәер, сезнең бер-ике дустыгыз да бардыр әле?

— Минем өч дустым бар, өчесе дә бик теләп минем белән бергә барачаклар.

— Өчәү дисезме? Бик шәп! Ничек туры килүен күр син! Минем дә дусларым өчәү бит,— диде д'Артаньян.

— Хәзер инде сез миңа үзегезнең кем икәнлегегезне дә әйтегез,— дип сорады инглиз.

— Мин, д'Артаньян, Гасконь дворяны, Дезэссар эфәнде ротасының гвардиячесе булам. Ә сез кем?

— Мин лорд Винтер, барон Шеффильд.

— Бик яхшы! Исемегез әйтер өчен бик кыен булса да, мин сезнең карамагыгызда, барон әфәнде,— диде д'Артаньян.

Шуннан соң ул атын шпорлый-шпорлый чаптырып кире Парижга кайтып китте.

Андый чактагы гадәтенчә, д'Артаньян туп-туры Атос янына барды.

Ул килеп кергәндә, Атос озын кушеткада, үзе әйтмешли, үзенә гаскәри кирәк-яраклар килгәнен көтеп ята иде.

Д'Артаньян барлык хәлне дустына сөйләп бирде, де Вардка дигән язу хакында гына бер сүз дә әйтмәде.

Атос, инглиз кешесе белән сугышачагын белгәч, бик сөенде. Аның шул хакта гел хыялланганлыгын без бер тапкыр әйтеп киткән идек инде.

Ике дус шундук, хезмәтчеләреннән Портос белән Арамисны чакыртып китертеп, хәлне аларга да сөйләп бирделәр.

Портос кылычын кынысыннан чыгарды да артка чигенгәләп һәм биючс кеше шикелле пднелар ясап, кылычы белән стенага кадарга кереште. Арамис исә, Атосның кабинетына бикләнеп алып, дуэль сәгате җиткәнче үзен борчымауларын үтенде — ул әле һаман теге поэмасын иҗат итә иде.

Атос Гримога ишарәләп кенә бер шешә шәрап китерергә кушты.

Д'Артаньянга килгәндә исә, ул күңеленнән кечерәк бер план кора иде. Без ул планның ничек чынга ашканын алдарак күрербез. Егетнең ара-тирә иреннәренә елмаюы чыгып, уйчан йөзе яктыргалап китүенә караганда, әлеге планы аңа күңелле генә бер мажара вәгъдә итә иде булса кирәк.

# *Икенче кисәк*

## I

## *ИНГЛИЗЛӘР БЕЛӘН ФРАНЦУЗЛАР*

Дүрт дус, хезмәтчеләрен ияртеп, сөйләшенгән вакытка Люксембург сарае артындагы ташландык җиргә килделәр. Киртәләп алынган бу төштә кәҗәләр генә көтәләр иде. Атос көтүчегә бераз вак акча биргәч, көтүче кайтып китте. Хезмәтчеләргә сакка басарга кушылды.

Озакламый әлеге төшкә, сүзсез-өнсез генә, бер төркем кеше килгәне күренде, болар да киртә эченә кереп, мушкетерларга кушылдылар; аннары, инглизләр гадәтенчә, үзара танышу башланды.

Атаклы, бай нәселдән чыккан инглизләр, дошманнарының бик сәер исемнәрен ишеткәч, гаҗәпләнү генә түгел, хәтта борчыла-шомлана ук башладылар.

— Мондый исемнәрдән безгә берни дә аңлашылмый әле,— диде лорд Винтер, өч дус үзләренең исемнәрен әйткәч,— без сезнең кемнәр икәнегезне белмибез һәм мондый исемле кешеләр белән сугышмаячакбыз. Ниндиде́р көтүче исемнәре бу,— диде.

— Сез бу исемнәрнең кушамат кына икәнлеген үзегез дә төшенә торгансыздыр, милорд,— диде Атос.

— Алай булгач, чын исемнәрегезне бигрәк тә беләсебез килә,— дип җавап кайтарды инглиз.

— Сез бит шакмак уйнаганда безнең исемне сорап тормаган идегез, хәтта икс атыбызны да отып киттегез,— дип куйды Атос.

— Сүзегез хак, ләкин ул вакытта без мал гына оттыра идек шул. Бу юлы инде җанны кыл өстенә куябыз: уйнаганда кем дә ярый, ә сугышканда — тиң кешеләр белән генә..

— Бу да хак сүз,— диде Атос һәм үзе белән сугышасы инглизне бер читкәрәк дәшеп алды да пышылдап кына үзенең чын исемен әйтте.

Портос белән Арамис та шулай иттеләр.

— Сез канәгатьме инде, мине үзегез белән кара-каршы сугышырлык, дәрәҗәле кеше саныйсызмы? — дип сорады Атос дошманыннан.

— Әйе, әфәндем,— диде инглиз, башын иеп.

— Бик яхшы! Ә хәзер мин сезгә бер нәрсә әйтим,— диде Атос салкын гына.

— Нәрсә? — диде инглиз гаҗәпләнеп.

— Сез минем исемемне әйттермәсәгез, әйбәтрәк булган булыр иде.

— Нигә?

— Чөнки мине дөньяда юк кеше дип саныйлар, минем исән булуымны беркемгә дә белгертмәскә тырышуымның сәбәпләре бар, шуңа күрә, серем дөньяга фаш булмасын өчен, хәзер мин сезне үтерергә тиеш булам.

Инглиз, шаяртадыр бу дип, Атоска күтәрелеп карады, ләкин шаярту дигән нәрсә Атосның уенда да юк иде.

Атос берьюлы дусларына да, дошманнарына да мөрәҗәгать итеп:

— Әзерләнеп беттегезме, әфәнделәр?— дип сорады.

Инглизләр белән французлар беравыздан:

— Әйе,— дип җавап кайтардылар.

— Алайса башлыйбыз!

Шул сүз әйтелүгә үк, баеп барган кояш яктысында ялык-йолык итеп сигез кылыч ялтырады; икеләтә дошман кешеләргә хас булганча, көрәш бик каты башланып китте.

Атос, фехтование залындагы шикелле, ашыкмыйча, иплән сугышты.

Шантильидагы теге хәл Портосның мин-минлеген беркадәр баса төшкән иде, күрәсең,— ул үзенең партиясен шактый хәйләкәр һәм сак уйнады.

Поэмасының өченче җырын язып бетерәсе булганлыктан, Арамис вакыты бик тыгыз кеше кебек ашыгып сугышты.

Иң элек Атос үзенең дошманын үтерде: бары бер генә тапкыр кадады ул аңа. Әмма, алдан кисәтеп куйганча, дошманын үтерерлек итеп кадады: кылыч очы тегенең йөрәген тишкән иде.

Шуннан соң Портос үз дошманын җиргә екты: ул аның ботын тишкән иде. Инглиз кешесе, карышудан туктап, кылычын Портоска бирде, һәм аннары мушкетер егет аны күтәреп каретага илтеп салды.

Арамис туктаусыз кыса-кысрыклый торгач, аның дошманы да ахырда түзмәде — илле адымнар чамасы чигенгәч, чатыр чабып кача башлады, хезмәтчеләр аның артыннан сызгырыпкөлеп калдылар.

Д'Артаньянга килсәк, ул гади генә һәм шул ук вакытта бик оста итеп саклану уены башкарды; аннары, дошманын ардыргач, бик каты сугып кулыннан кылычын бәреп төшерде. Инглиз бароны, коралсыз калуын күреп, берничә адым артка чикте дә абынып китеп чалкан егылды.

Д'Артаньян бер сикерүдә аның янына килеп җитеп, кылыч очын тегенең бугазына терәде.

— Мин сезне үтерә дә алам, әфәндем, сез минем кулда, ләкин сеңлегез хакына исән калдырам,— диде ул инглизгә.

Д'Артаньянның шатлыгы чамасыз иде; ул алдан уйлап куйган планын чынга ашырды, моннан берничә сәгать кенә элек әле, шул нияте чынга әйләнәсен уйлагач, сөенечле елмаюдан егетнең йөзе яктырып-яктырып китә иде.

Шундый әйбәт кеше белән эш итүенә бик сөенеп, инглиз бароны д'Артаньянны кочаклап алды, өч мушкетерга да бик күп мактау сүзләре әйтте. Портосның дошманы экипажга илтеп салынган, Арамисныкы исә качып киткән иде. Шуннан соң һәммәсе дә үлеп яткан инглиз белән шөгыльләнә башладылар.

Ярасы үләрлек үк түгелдер дип, Портос белән Арамис аны чишендерергә керештеләр, шул вакыт аның биленә кыстырган җиреннән акча тулы янчыгы килеп төште. Д'Артаньян янчыкны алып, лорд Винтерга сузды.

— Ә миңа нәрсәгә ул, шайтанымамы? — диде инглиз.

— Гаиләсенә кайтарып бирерсез,— диде д'Артаньян.

— Гаиләсенә бик кирәк иде ди андый чүп! Гаиләсе мираска унбиш мең луидор рента алачак. Хезмәтчеләрегезгә калсын ул янчык.

Шуннан соң д'Артаньян янчыкны кесәсенә салды.

— Ә хәзер, егетем,— сез миңа үзегезне дустым дип атарга рөхсәт итәрсез дип уйлыйм,— диде лорд Винтер,— каршы булмасагыз, мин сезне бүген кич үк сеңлем леди Кларик белән таныштырам. Мин аның да сезне үзенең дусты итүен телим. Король сараенда аны яхшы кабул итәләр, шулай булгач, әйткән сүзенең сезгә файдасы тиюе ихтимал.

Д'Артаньян мондый сүзгә бик күңеле булып кызарынып китте, ризалыгын белдереп баш иде.

Шул вакыт д'Артаньян янына Атос килде.

— Ул янчык белән нишләмәкче буласыз? — дип шыпыртлап кына сорады ул егеттән.

— Мин аны сезгә кайтармакчы идем, Атос дус.

— Миңа? Ни өчен алай?

— Чөнки янчык хуҗасын сез үтердегез бит. Җиңүченең табышы ул.

— Мин дошманымның варисы буламмыни?! Мине сез кем дип беләсез?

— Сугышның йоласы шундый бит,— диде д'Артаньян.— Ә нигә дуэльдә дә андый йола булмаска тиеш?

— Сугыш кырында да андый эш эшләгәнем юк минем,— диде Атос бу сүзгә каршы.

Портос җилкәсен генә сикертте. Арамис бу сүзне хуплап елмаеп куйды.

— Алайса, лорд Винтер тәкъдим иткәнчә, бу акчаны лакейларга бирик,— диде д'Артаньян.

— Яхшы, акчаны лакейларга бирербез, тик үзебезнекеләргә түгел. Инглизләрнең үз лакейларына бирәбез,— диде Атос һәм янчыкны алып кучерга ыргытты.

— Иптәшләрегез белән сезгә булыр.

Кесәсендә бер тиен акчасы булмаган кешенең мондый юмартлыгына хәтта Портосның да исе китте, һәм шуннан соң лорд Винтер белән аның дусты французлар юмартлыгы турында бөтен җирдә сөйләп йөрделәр. Гримо, Мушкетон, Планше һәм Базеннан кала, мондый юмартлыкка бөтен кешенең исе китте.

Д'Артаньян белән саубуллашкан чагында лорд Винтер аңа сеңлесенең адресын әйтте; лордның сеңлесе ул заманда модный квартал саналган Король мәйданында, 6 нчы йортта яши икән. Хәер, лорд Винтер д'Артаньян янына кереп, егетне сеңлесе белән үзе таныштырачагын әйтте. Д'Артаньян аның белән сәгать сигездә Атос квартирында очрашырбыз дип сүз куешты.

Миледи белән танышырга барачагы безнең Гасконь егетенең күңелен бик нык дулкынландыра башлады. Моңарчы үзенең язмышында шул хатынның ниндидер гаҗәп бер роль уйнавын исенә төшерде. Егет аның кардиналның бер агенты икәнлегенә шикләнмәсә дә, күңеле, акылына буйсынмыйча, ни сәбәптәндер аны шул хатынга тарта иде. Тик д'Артаньян бер нәрсәдән генә курка — миледи егетнең Мёнгта һәм Дуврда очраган бер кеше булуын хәтеренә төшермәгәе дип шикләнә иде. Ул чагында инде бу ханым аның де Тревиль әфәнденең дусты икәнлеген һәм, димәк, корольгә җаны-тәне белән бирелгән бер кеше булуын төшенәчәк, бу хәл исә ханым алдында егетнең беркадәр дәрәҗәсен киметәчәк иде, ә хәзер милединың егетне белүе д'Артаньянның аны белүе кадәр генә булганда, аларның уендагы шанслары бертигез иде. Милединың граф де Вард белән башлаган мәхәббәт интригасына килгәндә исә, граф яшь, чибәр, бай һәм кардиналның яраткан бер кешесе булса да, үз-үзенә нык ышанган Гасконь егетен ул мәхәббәт интригасы гына әллә ни борчымый иде. Ни дисәң дә, егеткә егерме генә яшь иде шул әле, өстәвенә, Тарбта туып үскән егет иде ул.

Иң элек д'Артаньян, өенә кайтып, бик әйбәтләп килеш-кыяфәтен рәткә китерде; шуннан соң янә Атос янына барып, гадәтенчә, аңа бөтен уй-ниятен сөйләп бирде. Атос аны тыңлап торды да, башын чайкап куеп, борчылган бер төстә дустына сак булырга киңәш итте.

— Ничек инде ул?! Әле бит сез яңа гына шундый әйбәт, чибәр, гүзәл дигән бер ханымнан аерылдыгыз, ә хәзер икенчесе артыннан чаба башлагансыз! — диде Атос егеткә.

Д'Артаньян бу шелтәнең бик урынлы булуын төшенде.

— Бонасье ханымны мин йөрәгем белән ярата идем, ә миледины акылым белән генә яратам,— диде ул бу сүзгә каршы.— Минем аның йортына керергә тырышуым асылда аның король сараенда нинди роль уйнавын ачыклау өчен генә бит.

— Нинди роль уйнавын, имеш! Үзегез сөйләгәннәргә кара-

ганда, аның нинди роль уйнаганлыгын чамалавы бер дә кыен түгел. Кардиналның ялерен бер агенты ул. Шул хатын сезне тозакка төшерәчәк тә башыгызны харап итәчәк — менә шул.

— Һе! Валлаһи, Атос дус, сез әйберне кирәгеннән артык кара итеп күрәсез.

— Нишлим соң инде, дустым, хатын-кызга ышанмыйм мин хәзер, минем моңа сәбәпләрем бар, бигрәк тә сары чәчле хатыннарга ышанмыйм. Сез бит миңа миледины сары чәчле дигән идегез шикелле?

— Искиткеч матур аксыл-сары чәчле, моңарчы минем андыйны күргәнем юк иде әле.

— Әй, бичара д'Артаньян! — дип көрсенеп әйтеп куйды Атос.

— Карагыз әле, мин бит эшнең хикмәтен генә белергә телим. Аннары, белгәч, китәм мин аннан.

— Алайса белегез инде,— диде Атос битараф бер төс белән.

Лорд Винтер сөйләшенгән вакытка Атос фатирына килеп керде. Атос, алдан искәртеп куелганлыктан, икенче бүлмәгә күчкән иде. Шулай итеп, инглиз килеп кергәндә д'Артаньян бүлмәдә үзе генә иде, сәгать сигез якынлашып килгәнгә күрә, лорд аны шундук алып чыгып та китте.

Аста аларны яхшы пар ат җигелгән бик купшы карета көтеп тора иде. Җитез атлар, күз ачып йомганчы, ике егетне Король мәйданына илтеп тә җиткерде.

Миледи Кларик д'Артаньянны салкын гына каршылады. Йорты бик бай, купшы икән; инглизләрнең күпчелеге сугыш аркасында Франциядән инде күчеп киткән булса яки китәргә җыенып ятсалар да, миледи әле яңа гына байтак акча тотып өен төзәттергән, бу хәл исә барлык инглизләрне илдән сөрү турындагы боерыкның аңа кагылмаганлыгын күрсәтә иде.

— Сезнең каршыгызда минем җанымны үз кулында тоткан яшь бер дворян басып тора. Без аның белән икеләтә дошман булсак та,— чөнки иң элек мин аны мыскыл иткән идем, аннары, мин инглиз кешесе дә бит әле,— ул әлеге форсаттан файдаланырга теләмәде. Ханым, әгәр мине аз гына булса да якын итсәгез, аңа рәхмәтегезне белдерегез,— диде лорд Винтер, сеңлесен д'Артаньян белән таныштырган чакта.

Миледи чак кына кашын җыерды, маңгаеннан сизелер-сизелмәс кенә бер күләгә узган сыман булды, иреннәре шундый сәер итеп елмайды — д'Артаньян, ханымның чыраендагы шушы катлаулы уенны күреп алгач, ирексездән калтыранып куйды.

Абыйсы моны сизмәде: нәкъ шул чакны аның камзул итәгенә мелединың сөекле маймылы килеп ябышкан, лорд, борылып, шуны сыйпарга керешкән иде.

— Бик хуш килдегез, әфәндем,— диде миледи ифрат бер йомшак тавыш белән, тик шунысы бик гаҗәп: тавышының аһәңе ханымның әле яңа гына д'Артаньянга сизелгән кәеф-

сезлегенә бер дә туры килми иде,— бүген сез мәңгелеккә минем ихлас рәхмәтемә ия булдыгыз.

Шул вакытны инглиз тагын боларга таба борылды да дуэльдә сугышулары турында тәфсилләп сөйләргә керешге. Миледи аны зур игътибар белән тыңлап торды; ул үзенең кичерешләрен яшерергә бик тырышса да, абыйсы сөйләгәннәрнең аңа ошамаганлыгы сизелеп тора иде. Ханым бер кызара, бер агарынып китә һәм сабырсызланып бәләкәй генә аяклары белән идәнгә типкәләп ала иде.

Лорд Винтер боларның берсен дә сизмәде. Дуэль хәлләрен сөйләп бетергәч, өстәл янына килде. Өстәлгә поднос белән бер шешә испан шәрабы һәм стаканнар куелган иде. Лорд Винтер ике стаканга шәрап салды да д'Артаньянга ишарәләп кенә эчеп куярга тәкъдим итте.

Инглизнең исәнлегенә шәраб эчүдән баш тарту аның бик нык хәтерен калдыру булачагын д'Артаньян аңлый иде. Шуңа күрә ул да өстәл янына килеп, икенче стаканны кулына алды. Шулай да үзе, мйледины күзәтә биреп, аның чырае үзгәреп киткәнлеген көзгедән күреп калды. Хәзер, миңа берсе дә карамый дип, уйланып утырган чагында ханымның чыраена ниндидер явызлык галәмәтләре чыкты. Ул яман бер ачу белән яулыгын тешләштергәләп утыра иде.

Шул минутта бүлмәгә теге сөйкемле, чибәр субретка килеп керде; ул лорд Винтерга инглизчә ниндидер сүз әйтте, һәм тегесе, бик ашыгыч эшем килеп чыкты дигән булып, д'Артаньяннан китәргә рөхсәт сорады, сеңлесенә үзе өчен тагын бер тапкыр гафу үтенергә кушты.

Д'Артаньян аның белән кул биреп саубуллашты да яңадан миледи янына килде. Ханым искиткеч бер тизлек белән баягыча чыраена тагын ачык, якты төс чыгарды, ләкин яулыгына иңеп калган берничә кызыл тап аның иреннәрен тешләштереп канатканлыгын әйтеп тора иде.

Ханымның иреннәре искиткеч матур — диңгез мәрҗәне төсле тонык кызыл иде.

Әңгәмә җанлана төште. Миледи инде үзен тәмам кулга алган иде булса кирәк. Ул д'Артаньянга лорд Винтер — аның үз абыйсы булмавын, бәлки иренең абыйсы гына икәнлеген әйтте. Миледи алар гаиләсендәге иң кече малайга кияүгә чыккан булган, ире аны бер бала белән тол калдырып үлеп киткән. Лорд Винтер өйләнмәсә, шул бала аның бердәнбер варисы булып калачак икән. Шушы сүзләрдән д'Артаньян боларда ниндидер бер серне яшереп тора торган пәрдә барлыгын тойды, тик хәзергә әле бу пәрдәне ул ача алмый иде.

Ярты сәгать чамасы гәп кылып утырганнан соң, д'Артаньян милединың үзенең ватандашы икәнлегенә ышанды; ханым французча шул хәтле дөрес, матур итеп сөйләшә — аның милләте француз булуына бернинди шик туарлык түгел иде.

Д'Артаньян, әңгәмәдәшенә тугрылыклы булачагына ышан-

дырырга тырышып, тәмле телен кызганмады. Миледи Гасконь егетенең әнә шулай теленә салынуын ошаткан-хуплаган кебек елмаеп кына тыңлап утырды. Аннары инде егеткә кайтып китәргә дә вакыт җитте. Д'Артаньян ханым белән саубуллашты да, дөньяда үзен иң бәхетле бер кеше сыман хис кылып, кунак бүлмәсеннән чыгып китте.

Баскычтан төшеп барган чагында каршысына теге сөйкемле субретка очрады. Кыз егет яныннан узганда аңа чак кына кагылып китте дә, колак очларына хәтле кызарынып, искиткеч ягымлы, назлы бер тавыш белән д'Артаньяннан гафу үтенде — әлбәттә, шундый тавышлы матур кызны гафу итми мөмкин түгел иде.

Иртәгесе көнне д'Артаньян бу йортка тагын килде, аны кичәгедән дә ачыграк чырай белән каршы алдылар. Бу юлы инде биредә лорд Винтер юк иде, кичнең кич буе кунак белән миледи үзе генә шөгыльләнде. Егет белән бик кызыксынды шикелле ул, аның тумышы белән кайсы яктан икәнлеген, дуслары кем булуын сорашты, кардиналга хезмәткә керергә теләгегез булмадымы? — дип сорады.

Белгәнебезчә, д'Артаньян әле егерме яшендә генә булса да, шактый сак, зирәк бер егет иде. Бу сорауны ишеткәч, ул миледига карата булган шик-шөбһәләрен исенә төшерде; миледи каршында кардинал хәзрәтләрен бик мактап телгә алды, әгәр мин, де Тревиль әфәндене белгән кебек, де Кавуа әфәндене дә яхшы белгән булсам, король гвардиясенә түгел, бәлки кардинал гвардиясенә кергән булыр идем, диде.

Миледи җайлап кына сүзне икенчегә күчерде дә, бер дә исе китмәгән сыман, егеттән: Англиядә булганыгыз бармы? — дип сорады.

Д'Артаньян, ул илгә де Тревиль әфәнденең кушуы буенча атлар сатып алу хакында сөйләшергә барган идем, күрсәтү өчен хәтта дүрт ат та алып кайттым, дип җавап бирде.

Шушы әңгәмә дәвамында миледи ике-өч тапкыр иренен тешләде: бик хәйләкәр сөйләшә иде шул бу Гасконь егете.

Д'Артаньян нәкъ кичәге вакытта саубуллашып чыгып китте. Коридорда каршысына тагын сөйкемле Кэтти очрады — кызның исеме шулай икән. Кэтти егеткә шундый яратып, шундый матур итеп карады — моның мәгънәсен сизми калу мөмкин түгел иде, тик д'Артаньянның бөтен күңелен кызның байбикәсе яулап алган, егет фәкать аның чыраендагы мәгънәләрне генә сизә иде.

Д'Артаньян миледи янына икенче, өченче көнне дә барды һәм килгән саен миледи аны ачыграк чырай белән каршы ала башлады.

Һәр кичне әле алгы бүлмәдә, әле коридорда, әле баскычта егетнең каршысына сөйкемле субретка очрый торды.

Ләкин, әйткәнебезчә, д'Артаньян бичара Кэттиның бу тырышлыгына карата аз гына да илтифат билгесе күрсәтмәде.

## II

## ПРОКУРОРЛАРДА АШ МӘҖЛЕСЕ

Хәлбуки, Люксембург сарае артында булган теге дуэль дә, шунда Портосның зур каһарманлык күрсәтүе дә прокурорларда булачак аш мәҗлесен оныттырмады. Икенче көнне, сәгать уникедән соң, Мушкетон соңгы тапкыр хуҗасының өс-башын щетка белән сыпыргалап алды да, Портос, юлында гел бәхет кенә очрап торган бер кеше сыман, Аю урамына китте.

Түземсез яшь мәхәббәт дәрте белән ашкынып типкән д'Артаньян йөрәге шикелле үк булмаса да, Портосның да йөрәге җилкенеп тибә, тик аны башка бер дәрт, үз кирәген кайгырту уе җилкендерә: менә хәзер ул әлеге серле бусага аша атлап керер дә таныш булмаган баскычтан өскә күтәрелер — метр Кокнарның шул баскыч буйлап берәм-берәм өенә җыела килгән иске экюлары янына менәр.

Ничәмә-ничә тапкыр төшләрендә күргән серле сандыкны менә хәзер ул өенендә, үз күзе белән күрер — озындыр, тирәндер ул сандык, идәнгә берегеп, күгәреп беткәндер, аны ат башы чаклы йозак белән бикләп куйганнардыр. Әнә шул бик мәгълүм сандыкны менә хәзер прокурор хатыны беркадәр корыша башлаган, шулай да әле нәфислеген югалтып бетермәгән куллары белән Портос алдында ачып җибәрер.

Моның өстенә әле ул,— йортсыз-җирсез, җәмәгатьсез, малмөлкәтсез бер мосафир, постоялый двор һәм трактирларда, таверна һәм кабакларда йөреп гадәтләнгән, тәмле ашарга яратучы, ә күбесенчә ни эләксә шуның белән тамак туйдыручы бер солдат,— менә хәзер өйдә пешкән тәмле-тәмле ашлар ашар, шунда гаилә җылысы тоеп рәхәтләнеп утырыр һәм, кунак буларак, үзен үтереп кыстаучы хуҗабикә карамагына тапшырыр. Карт солдатлар әйтмешли, хуҗа ханым никадәр катырак кыстаса, кунакка шулкадәр рәхәтрәк була бит.

Хуҗа ханымның туганнан туган энесе булып, көн саен мул ризыклы табынга килеп утыру, карт прокурорның кәефен күреп, саргайган маңгаендагы җыерчыкларын язылдырып җибәрү, яшь писерләрне бассет, гальбик һәм ландскнехт уеннарының иң нечкә хәйләләренә өйрәтеп, сәгатьле дәрес биргән өчен гонорар алган кебек, аларның ай буе җыйган акчаларын отып бераз каурыйларын йолку — Портосның күңеленә бик хуш килерлек шөгыль иде болар.

Хәер, мушкетер егет ул заманда прокурорлар турындагы әллә кайчангы искереп беткән гайбәтләрне дә исенә төшерде — имеш, алар бик вакчыл, комсыз һәм саран халык; ләкин прокурор хатынының акчаны бәрәкәтләп тотам дигән булып вакыт-вакыт саранланып китүен исәпкә алмаганда (Портос сөяркәсенең бу гадәтен ошатып бетерми иде, әлбәттә) — ханым ярыйсы ук юмарт кеше иде,— билгеле инде, үзе өчен,— шуңа

күрә Портос аларның йортында иркенлектер, муллыктыр дип күз алдына китерә иде.

Ләкин ишек төбенә килеп җиткәч, мушкетер егетнең күңеленә беркадәр шик керде — ишектән алып өй эченә кадәр булган ара бигүк ямьледән түгел иде: коридорлары шакшы, сасы ис аңкып тора, баскычлары ярым караңгы, аның рәшәткәле тәрәзәсе аша күрше йортның ишегалдыннан саран гына яктылык саркып керә; икенче катның ишеге тәбәнәк, Гран-Шатле төрмәсенең үзәк ишеге шикелле, эре-эре кадаклар сугып бетерелгән иде.

Портос ишек шакыды; тубалдай чәче тузгып битләренә хәтле кайтарылып төшкән озын буйлы, ак чырайлы бер писер килеп ишекне ачты һәм көчле икәнлеген белгертеп торган буйчан кешеләрне, җәмгыятьтә билгеле бер дәрәҗә тоту билгесе булган гаскәри мундирны һәм иркен, мул яшәргә яратканны күрсәтә торган таза-көр чырайны бик ихтирам итәм дигән сыман бер төс белән бөгелеп баш иде.

Беренчесе артыннан тәбәнәгрәк буйлы икенче писер дә күренде; икенчесе артыннан бераз калкурак гәүдәле өченчесе килде, өченчесе артыннан унике яшьләр чамасындагы бер малай күренде.

Өч ярым писер тоту ул заманда конторның шактый күп клиент белән эш иткәнлеген белгертә иде.

Мушкетер егет көндезге сәгать бергә генә килеп җитәргә тиеш булса да, прокурор хатыны сөйгән егетен, я йөрәге, я ач карыны түзмичә, иртәрәк килер дип, төш алдыннан ук көтә башлаган иде.

Шулай итеп, Кокнар ханымның кунагы нәкъ ишек төбенә килеп җиткән чакта гына баскыч алдына хуҗабикә үзе дә чыгып, егетне шактый кыен хәлдән коткарды. Писерләр кунакны бик кызыксынып карап торалар. Портос исә, берсе озын, икенчесе кыска буйлы бу кешеләргә ни дип әйтергә дә белмичә, телен йотып басып тора иде.

— Минем тудыкам ул! — дип кычкырып әйтте прокурор хатыны.— Керегез, керегез инде, Портос әфәнде.

Портос дигән исем писерләргә дә тәэсир итми калмады, алар көлешә башладылар, әмма Портос үзләренә таба борылуга — тагын җитдиләнеп калдылар.

Прокурорның кабинетына эләгү өчен хәзер писерләр җыелышып торган алгы бүлмәдән алар утыра торган контор аша — кәгазь белән тулган караңгы бер бүлмә аркылы узарга кирәк икән. Контордан чыгып, кухняны уң тарафта калдырганнан соң гына кунак белән хуҗа ханым кабинет алдындагы бүлмәгә килеп керделәр.

Берсеннән берсенә үтеп йөрешле бу бүлмәләр дә Портоста әллә ни күңелле тәэсир калдырмады. Мондагы ачык ишекләр аша һәр әйткән сүзең ишетелеп тора булырга тиеш; аннан тыш, узышлый гына кухня ягына күз төшереп алгач, мушкетер

егет,— прокурор хатынының оятына һәм үзенең гаҗәбенә каршы,— анда дөрләп янган ут та, ашау өчен генә яшәүчеләр йортында яхшы мәҗлес алдыннан була торган ыгы-зыгы да күрмәде.

Хатынының туганнан туган энесе киләсен прокурор белә иде күрәсең, Портос килеп кергәч, аңа бер дә гаҗәпләнмәде. Кунак, үзен бик иркен тотып, аның янына килде дә әдәп йөзеннән бөгелеп баш иде.

— Без сезнең белән кардәшләр бугай, Портос әфәнде? — дип сорады прокурор һәм камыш креслосының култыксаларына таянып бераз калкына төште.

Корышып, бәлтерәп беткән бер карт иде бу өстендәге иркен кара камзулы аның ябык, зәгыйфь гәүдәсен каплап-яшереп тора; кечкенә генә соры күзләре ике сызлавык шикелле елтырап тора һәм аның йөзендә тереклек билгесе булып әнә шул ике күзе белән кыеш-мыеш килеп торган авызы гына калгандыр сыман иде. Бәхетсезлегенә каршы, бу шыр сөяк гәүдәнең аяклары да йөрми башлаган һәм, моннан биш-алты ай элек шул хәлгә төшкәч, мөхтәрәм прокурор асылда хатынының колына әйләнгән иде.

Хуҗа ханымның туганнан туган энесен сыкранмыйча-зарланмыйча гына кабул иттеләр, шуннан да артыгы булмады. Метр Кокнар, әгәр үз аягы белән йөрерлек хәлдә булса, Портос әфәнденең туган-тумачалык дәгъвасын ишетергә дә теләмәс иде, әлбәттә.

— Әйе, әфәндем, кардәшләр икәнбез шул,— диде Портос бер дә уңайсызланмыйча; хәер, андый ирләрнең үзен ачык чырай белән каршы алуларына исәп тотканы да юк иде аның.

— Кардәшлек хатын ягыннан бугай? — дип эченнән генә көлеп сорады прокурор.

Портос аның бу көлүен сизмәде, мондый соравын прокурорның ихлас күңеллегеннән дип белеп, куе мыегы астыннан елмаеп кына куйды. Кокнар ханым исә, ихлас күңелле прокурорлар дөньяда бик сирәк икәнен яхшы белгәнгә күрә, чак кына көлемсерәп куйды, битләре кып-кызыл булып кызарып китте.

Портос килү белән үк метр Кокнар үзенең имән конторкасы каршындагы дәү шкафка борчылып күз салгалый башлады. Портос бу шкафның, формасы үзгәрәк булса да, төшләрендә күргән теге сандык икәнлеген бик тиз төшенеп алды һәм күңеленнән үзен чынбарлыкның хыялдан алты футка биегрәк булуы белән тәбрик итте.

Метр Кокнар кардәшлек тамырларын бүтән тикшерәсе-төпченәсе итмәде, борчулы карашын шкафтан Портоска күчерде дә:

— Походка чыгып киткәнче, тудыкабыз бер генә тапкыр булса да безнең белән табындаш булыр дип өметләнәм, шулаймы, Кокнар ханым? — дип кенә куйды.

Бу юлы инде прокурорның бу сүзе Портосның ач карынына китереп сукты, мушкетер егет шул вакыт эченең сулкылдап авыртып куюын тойды, моны Кокнар ханым да сизде булса кирәк, чөнки ул болай дип сөйләнде:

— Кунак итүебез ошамаса, тудыкам безгә бүтән килмәс тә инде, әгәр ошатса, походка киткәнче бөтен буш вакытын диярлек безгә багышлавын үтенербез,— Парижда озак тора алмый бит ул, безгә дә күп килә алмый.

— Ай аякларым, бичара аякларым, кайда соң сез? — диде метр Кокнар, елмаерга тырышып карады.

Портосның карын мәсьәләсенә җитди куркыныч туарга торган бер мизгелдә шундый ярдәм килүе мушкетер егетнең күңелендә прокурор хатынына карата зур рәхмәт тойгылары кузгатты.

Озакламый табынга утырыр вакыт та җитте. Бөтен кеше кухня каршындагы аш бүлмәсе дигән зур бүлмәгә күчә башлады.

Писерләр өйдәге тәмле аш исләрен сизеп торганнар, күрәсең,— гаскәриләрчә нәкъ вакытында килеп керделәр һәм, утыргычларын кулларына тоткан килеш, табынга утырырга әзер булып басып тора башладылар. Аларның теш-казналары, барысын чәйнибез, барысын урабыз дигәндәй, алдан ук селкенә-хәрәкәт итә башлаган иде инде.

Портос, бу ачәрвахларга күз төшереп алып (малайны, әлбәттә, табынга утыртмыйлар иде), эченнән генә: «Ай-һай-һай! — дип куйды.— Тудыкам урынында булсам, мин бу гуҗларны йортымда тотар идемме! Кораблары һәлакәткә очрап, алты атна буе ризык күрмәгән әдәмнәр шикелле бит болар».

Аш бүлмәсенә метр Кокнар да керде; аны тәгәрмәчле креслосы белән Кокнар ханым үзе этеп кертте. Портос, шунда йөгереп килеп, аны өстәл янына китерергә булышты.

Аш бүлмәсенә керү белән, прокурорның да, писерләренеке шикелле, теш-казналары хәрәкәтләнә, борын канатлары селкенгәли башлады.

— Оһо! Ашның исе нинди тәмле! — дип куйды ул.

«Нәрсәсенә шаккаталар бу ашның?» — диде күңеленнән Портос, чырайсыз гына ашны күреп. Дөрес анысы, аш күп, ләкин аның өстендә май тәңкәсенең әсәре дә юк, архипелаг атаулары шикелле, анда-санда гына кыздырган икмәк кисәкләре генә күренгәли иде.

Кокнар ханым елмаеп куйды, һәм ул утырышыгыз дип ишарә ясауга, барысы ашыга-ашыга табын тирәсенә урнаштылар.

Иң элек метр Кокнарга, аннары Портоска аш бирделәр; шуннан соң Кокнар ханым ашын үз тәлинкәсенә салды һәм кыздырган икмәк кисәкләрен, шулпасыз гына, түземсезләнеп аш көтеп утырган писерләргә бүлеп бирде.

Шул вакытны шыгырдап аш бүлмәсенең ишеге ачылды һәм

яртылаш ачык ишектән Портоска теге писер малай күренде. Ул, табынга утыра алмагач, кухня белән аш бүлмәсендәге тәмле исләрне иснәп-иснәп, шунда икмәген чәйнәп тора иде.

Аштан соң асрау кыз пешкән тавык китерде. Бу тансык азыкны күргәч, табындагыларның күзләре шар булды.

— Кардәшләрегезне бик яратканлыгыгыз күренеп тора, Кокнар ханым,— диде прокурор авыр гына елмаеп.— Һичшиксез, мондый тәмле ризыклар өчен без сезнең тудыкагызга бурычлыбыздыр.

Бичара тавык шундый арык, төкле тиресе шул кадәр калын — аны бернинди сөяк тә тишеп чыгарлык түгел иде; мөгаен, аны, бик озак эзли торгач, кунакчасыннан табып алганнардыр, ул бичара инде картаеп тыныч кына үлим дип шунда качкан булгандыр.

«Бик күңелсез хәл, шайтан алгыры! Картлыкны хөрмәт итсәм дә, пешергән, кыздырган хәлендә булмасын иде ул»,— дип уйланды Портос.

«Минем бу фикеремне уртаклашучы бар микән?» дигән сыман як-ягына күз салды. Каршысында гына әлеге искиткеч шәп тавыкны йотардай булып карап торган ач күзләрне күрде.

Кокнар ханым тавык салган савытны үзенә табарак тартты да ике зур күм-күк ботны оста гына каерып алып, иренең тәлинкәсенә салды, муенын кисеп, башы белән бергә, үзенә дип, читкәрәк алып куйды, Портос тәлинкәсенә тавыкның канатын салды. Шуннан соң бөтен түшкәсен диярлек асрау кызга бирде, һәм Портос тавык өмет итеп утыручыларның характер, темпераментларына карап йөзләрендә нинди үзгәреш туганын күреп өлгергәнче, тавык юкка да чыкты.

Тавык урынына табынга зур савыт белән ногыт борчагы китерделәр. Аның өстендә берничә сарык сөяге дә күренә, карап торуга ите дә бар сыман иде.

Ләкин писерләр монысына инде алданмадылар, моңарчы алар бик күңелсез чырай белән утырган булсалар, хәзер исә язмышларына буйсынган бер кыяфәткә керделәр.

Кокнар ханым, бик әйбәт хуҗа хатын сыман бер төс белән, бу ашамлыкны егетләргә бүлеп бирде.

Шәрабка да нәүбәт җитте. Метр Кокнар кечкенә генә керәч шешәдән егетләргә стаканнарының өчтән беренә кадәр генә шәраб салды, үзенә дә шул чаклы гына агызды, шуннан соң шешә Портос белән Кокнар ханым ягына күчте.

Егетләр тулып җитмәгән стаканнарын су белән тутыра төштеләр, аннары, стаканнарын яртысына хәтле эчкәч, тагын су өстәделәр, һәм аш мәҗлесе беткәнче, эчә торган эчемлекләренең төсе кызыл якут төсеннән сыек кына алсу топаз төсенә кергәнче су өсти тордылар.

Портос кыяр-кыймас кына чемченгәләп тавык канатын ашап бетерде һәм өстәл астында үзенең ботына прокурор хаты-

нының тез башы орынганын тоеп сискәнеп китте. Бу йортта бик бәрәкәтләп кенә тотыла торган әлеге шәрабны ул да ярты стакан эчеп куйды һәм бу шәрабның бик нечкә татымлы кешеләрнең гайрәтен чигерә торган әшәке, тәмсез монрейль эчемлеге икәнен белде.

Метр Кокнар аның шәрабны су кушмыйча гына эчкәнен карап торды да авыр сулап куйды.

— Менә бу ногытны да ашап карагыз, тудыкам Портос,— диде Кокнар ханым, ә үзенең тавышы: «Ихластыр, ашый күрмәгез!» — дигән сыман иде.

«Ашамый ни, орынмыйм да мин ул ногытка»,— дип үз алдына гына мыгырданып куйды Портос.

Аннары кычкырыбрак:

— Рәхмәт, тудыкам, мин тук инде,— диде.

Табында тынлык урнашты. Портос нишләргә белмичә пошына башлады. Прокурор берничә тапкыр:

— Һай, Кокнар ханым, бик зур рәхмәт инде сезгә, бер дигән ашлар белән сыйладыгыз безне. Йа алла! Тәмам туйганчы ашадым! — дигән сүзен кабатлады.

Метр Кокнарның бөтен ашаганы бер тәлинкә аш, күм-күк ике тавык боты һәм аз-маз гына итле сарык сөяге булды.

Портос аның бу сүзен үзенчә көлүедер дип уйлады һәм, кашларын җыергалап, мыегын бөтергәли башлаган иде дә, Кокнар ханымның тез башы аңа әкрен генә кагылып алып, сабыр булырга киңәш итте.

Табындагы мондый сүзсезлек һәм ашау-эчүдән туктау Портоска бөтенләй аңлашылмаса да, писерләр өчен мәгънәсе бик яман иде аның: прокурорның күз карашындагы ымга буйсынып (шул вакыт Кокнар ханым елмаеп куйды) алар әкрен генә табын яныннан тордылар, тагын да әкренрәк итеп салфеткаларын өстәл өстенә бөкләп салдылар да, баш иеп, ишеккә таба киттеләр.

— Барыгыз, егетләр, эшкә керешегез, эш ул аш сеңдерергә бик файдалы,— диде прокурор җитди бер төс белән.

Писерләр чыгып китү белән, Кокнар ханым, урыныннан торып, буфеттан бер кисәк сыйр, айва вареньесы һәм бал белән кушып үзе пешергән миндаль пирогы чыгарды.

Бу кадәр сый-нигъмәтне күргәч, метр Кокнар кашын җыерды. Портос исә, үзенең ярым ач калганлыгын аңлап, иренен тешләде.

Ул, ногыт борчагы бармы әле дип, табынга күз салса,— ногыт борчагы да юкка чыккан иде инде.

Метр Кокнар, креслосында кыбырсый башлап:

— Менә бу — сый, ичмасам! — дип куйды.— Чын сый бу, epulae epularum; Лукулл Лукулл янында сыйланып утыра.

Портос, шәраб, ипи һәм сыйр белән тамак туйдырмаммы дип, үзе янындагы шешәгә күз төшергән иде — шәраб беткән,

шешә бушаган булып чыкты. Кокнар әфәнде белән хуҗа ханым моны бөтенләй күрмәгәнгә салыштылар.

«Бик яхшы, ярый әле миңа искәртеп куйдылар»,— дип уйланды Портос.

Бер кашык варенье алып капты, һәм Кокнар ханымның җилем кушкан сыман пирог камыры Портосның тешләренә сыланды.

«Корбаным бирдек. Их, Кокнар ханым белән икәү иренең шкафына күз салырга өметләнмәгән булсам!» — дип күңеленнән үз-үзенә сөйләнде егет.

Кокнар әфәнденең, бик шәп сыйланганнан соң (моны ул типтереп алу дип тә атады), ял итәсе килде. Ул хәзер үк шушында гына ял итә башлар дип өметләнгән иде Портос, тик нәләт төшкере прокурор бу хакта ишетергә дә теләмәде: аны кабинетына илтеп куярга туры килде, шкафы янына җитмичә кычкыруыннан туктамады, ышанычлырак булсын өчен аякларын шкаф кырыена терәп утырды.

Прокурор хатыны Портосны күрше бүлмәгә алып чыгып китте һәм шунда татулашуның нигезен җайларга керешге.

— Сез атнасына өч тапкыр төшке ашка килә аласыз,— диде Кокнар ханым.

— Рәхмәт, тик мин артык әрсезләнергә яратмыйм шул. Аннары гаскәри кирәк-яракны да кайгыртасым бар,— диде Портос.

— Ә, әйе шул... Һаман да шул кирәк-ярак бит әле, бәла! — дип сыкранып куйды прокурор хатыны.

— Кызганычка каршы, шулай шул, аны кайгыртасы бар,— дип җөпләде Портос.

— Сезнең полкта ул кирәк-ярак нидән гыйбарәт инде, Портос әфәнде?

— О, байтак нәрсәдән гыйбарәт ул,— диде Портос.— Үзегезгә мәгълүм, мушкетерлар — бер дигән сайланма гаскәр, шуңа күрә аларга, гвардиячеләр белән швейцарлыларга караганда, тагы бик күп әйбер кирәк.

— Нинди әйберләр инде ул? Атап әйтегез әле.

Портосның нинди әйберләр кирәклеге турында аерым-аерым атап түгел, тулаем гына дәгъвалашасы килә иде, шуңа күрә сүзен болай дип башлады:

— Аның инде бөтен бәһасы...

Прокурор хатыны, эченнән калтырана-калтырана, Портосның әйтеп бетергәнен көтте.

— Бәһасы күпме? — дип сорады.— Минемчә, алай ук... тегә... нидән артык түгелдер...

Ханым, тыны буылып, сүзен әйтә алмады.

— Юк, юк,— диде Портос,— ике мең ярым ливрдан да артык кирәк булмас. Билгеле бер экономия белән эш иткәндә, ике меңе дә җитәр әле дип уйлыйм.

— Йа хода! Ике мең ливр! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды Кокнар ханым.— Бу үзе бер байлык бит.

Портос бик гаҗәпләнгән сыман мәгънәле генә итеп кашларын җыерды. Һәм Кокнар ханым моны шундук аңлап та алды.

— Кирәк-ярагыгыз нидән гыйбарәт дип соравым шуңа,— дип төшендерергә кереште ханым,— сәүдә дөньясында минем байтак кына туган-тумачам һәм клиентларым бар. Сезгә кирәк әйберләрне, сез алгандагыга караганда, бермә-бер арзангарак юнәтә алырмын дип ышанам.

— Ах, алаймыни! Ул чагында башка эш,— диде Портос.

— Әлбәттә, шулай, сөекле Портос әфәнде! Димәк ки, беренче нәүбәттә сезгә ат кирәк, әйеме?

— Әйе, ат кирәк.

— Бик яхшы, сезгә кирәкле ул нәрсә миндә бар.

— Шулаймыни?! — диде Портос ачылып китеп.— Димәк, ат мәсьәләсе хәл ителде. Шуннан соң инде миңа тулысы белән ат дирбиясе кирәк, ләкин ул дирбиягә керә торган әйберләрне мушкетер үзе генә ала ала. Хәер, анысының хакы өч йөз ливрдан артык булмастыр.

— Өч йөз ливр! Нихәл итмәк кирәк, ярый инде — өч йөз ливр булсын,— диде прокурор хатыны ут йотып.

Портос елмаеп куйды. Аның инде герцог Бекингэм бүләк иткән няре барлыгын укучы хәтерли торгандыр, шуңа күрә Портос әлеге өч йөз ливрны кесәсенә генә салып куярга чамалый иде.

— Аннары, хезмәтчемә ат, үземә чемодан кирәк,— диде ул сүзендә дәвам итеп.— Корал мәсьәләсенә килгәндә, анысы өчен борчылмасагыз да була: коралым бар.

— Хезмәтчегә ат! — дип куйды прокурор хатыны кыяркыймас кына.— Беләсезме, дустым, монысы инде чамадан артык булыр.

— Шулаймыни, ханым?! — диде Портос тәкәббер генә.— Сез мине берәр хәерче дип беләсезме әллә?

— Юкны сөйләмәгезсәнә! Матур гына качыр да ярый, аттан бер дә ким түгел ул, дип кенә әйтмәкче идем мин. Минемчә, Мушкетон өчен матур гына бер качыр алсагыз...

— Ярый, матур гына качыр булсын,— диде Портос.— Сүзегез хак, минем үземнең дә бөтен яраннары качырга атланган бик атаклы испан вельможаларын күргәнем бар. Ул чагында инде, Кокнар ханым, үзегез беләсез, әлеге качырга чук белән шөлдер дә кирәк булыр.

— Анысы өчен борчылмагыз,— диде прокурор хатыны.

— Хәзер инде чемодан мәсьәләсе,— дип сүзендә дәвам итте Портос.

— О, анысы өчен дә борчылырга тиеш түгелсез! — дип тавышын күтәрә төшеп әйтеп куйды Кокнар ханым.— Иремнең бишме-алтымы чемоданы бар, иң яхшысын сайлап алыр-

сыз. Юлга чыккан чагында ул берсен бигрәк тә ярата иде: анысы шундый зур — бөтен дөнья әйберсен сыйдырырлык.

— Алайса, ул чемодан буш? — дип сорады Портос ихлас күңелдән.

Прокурор хатыны да ихлас күңелдән:

— Әлбәттә, буш,— дип җавап кайтарды.

— Кадерлем, миңа бит буш чемодан гына түгел, аңа саласы әйберләре дә кирәк! — диде Портос тавышын күтәрә төшеп.

Кокнар ханым тагын ут йотарга керешә. Ул чагында әле Мольер үзенең «Саран» дигән комедиясен язмаган иде. Шулай итеп, Кокнар ханым Гарпагоннан алдарак туган булып чыга иде.

Кыскасы, кирәк-яракның калган өлеше дә шул рәвешчә бик җентекләп тикшерелде, һәм шушы киңәшмә нәтиҗәсендә прокурор хатыны сигез йөз ливр акча бирергә, шуның өстенә, Портос белән Мушкетонны дан-шөһрәт юлына алып китәсе ат белән качырны юнәтергә дә үз өстенә бурыч алды.

Шул шартларны сөйләшеп килешкәннән соң, Портос Кокнар ханым белән саубуллашып кайтып китте. Дөрес, ханым күз кыскалап аны китми торырга да кыстап караган иде дә, Портос, хезмәткә барасым бар, дигәч, прокурор хатыны аны король карамагына җибәрергә тиеш булды.

Мушкетер егет ярым ач һәм бик кәефсез хәлендә өенә кайтып китте.

## III

## *СУБРЕТКА ҺӘМ АНЫҢ БАЙБИКӘСЕ*

Инде әйтеп үткәнебезчә, д'Артаньян, Атосның акыллы киңәшләренә һәм үзенең вөҗданы борчылуына да карамастан, миледига торган саен ныграк гашыйк була барды. Шуңа күрә тәвәккәл Гасконь егете, миледи янына көн саен барып, аның күңелен яуларга тырышуында дәвам итте, иртәме-соңмы дигәндәй бу яшь ханымның да егеткә шундый ук мөнәсәбәт күрсәтәчәгенә өметен өзмәде.

Беркөнне кич, «мин булдыра алмаган эш дөньяда юк ул» дигән сыман бик кәефле бер төс белән бирегә килгәч, егет капка төбендә теге субретканы очратты; тик бу юлы сөйкемле Кэтти егеткә узышлый кагылып кына калмады,— бәлки аны яратып кулыннан ук тотты.

«Бик шәп бит әле бу! Байбикәсенең миңа берәр йомышын әйтмәкчедер. Миледи минем белән күрешәсе килүен үзе әйтергә кыймагандыр да хәзер бу әйтәдер»,— дип уйлады д'Артаньян.

Һәм егет «күрдегезме, мин булдыра алмаган эш юк ул дөньяда» дигән сыман бер төс белән чибәр кызга карады.

— Әфәндем, минем сезгә әйтәсе сүзем бар иде...— диде кыз кыяр-кыймас кына.

— Әйт, сеңлем, әйт, мин тыңлыйм,— диде д'Артаньян.

— Мин аны монда гына әйтә алмыйм шул: минем сезгә әйтәсе сүзем артык озын, аннан да бигрәк бик яшерен сер.

— Алайса нишлик соң?

— Әгәр дә кавалер әфәнде минем белән барырга риза булса...— диде Кэтти кыяр-кыймас кына.

— Теләсәгез кая барам, матурым.

— Ул чагында әйдәгез.

Кэтти, д'Артаньянның кулын ычкындырмыйча, егетне борылмалы-сырылмалы караңгы баскыч буйлап алып менеп китте; унбишләп басма менгәннән соң, бер ишекне ачты.

— Керегез, әфәндем, монда бездән башка беркем юк, сүзебезне иркенләп сөйләшербез.

— Бу кем бүлмәсе соң, матурым? — дип сорады д'Артаньян.

— Минеке, әфәндем, менә бу ишек байбикәмнең йокы бүлмәсенә чыга, тик сез борчылмагыз, безнең сүзне миледи ишетмәс, ул беркайчан да төн уртасы җитмичә йокы бүлмәсенә керми.

Д'Артаньян бүлмә эченә күз салды. Кечкенә генә бу ямьле бүлмә бик чиста-пөхтә итеп зәвык белән җыештырылган иде, шулай да егет, ихтыярыннан тыш, әлеге, милединың йокы бүлмәсенә чыга торган ишектән күзен ала алмады.

Кэтти, егетнең кичерешләрен сизеп, авыр сулап куйды.

— Минем байбикәмне сез шулай бик яратасызмыни, әфәндем? — дип сорады.

— Әйе шул, Кэтти, тел белән генә әйтеп бирә торган түгел, шашып яратам!

Кыз тагын авыр сулап куйды.

— Бик кызганыч хәл, әфәндем! — диде.

— Нигә алай бик кызганыч икән соң ул, шайтан алгыры? — диде егет.

— Чөнки байбикәм сезне тамчы да яратмый, әфәндем,— диде Кэтти.

— Һе! — дип куйды д'Артаньян.— Син моны аның кушуы буенча әйтмисеңдер ич?

— Юк, әфәндем, юк! Сезне кызганганга күрә әйтәм мин моны.

— Яхшы ният белән әйтсәң, бик рәхмәт, сөекле Кэтти, чөнки, үзең дә бик яхшы аңлыйсыңдыр — минем өчен бигүк сөенечле хәбәр түгел бу.

— Икенче төрле әйткәндә, сез минем сүземә ышанмыйсыз, әйеме?

— Горурлыкка тия торган андый сүзгә ышануы кыен шул, матурым.

— Димәк, сез минем сүзгә ышанмыйсыз?

— Ихластыр, бу сүзеңне расларлык бирәр дәлил китермичә ышана алмыйм шул.

— Ә менә мона ни диярсез икән?

Шулай дип, Кэтти изү эченнән кечкенә бер хат чыгарды.

— Миңамы бу? — диде д'Артаньян, хатны кызның кулыннан алып.

— Юк, икенче берәүгә.

— Икенче берәүгә?

— Әйе.

— Ул кешенең исеме, исеме?! — дип кычкыра төшеп сорады д'Артаньян.

— Адресын карагыз.

— Граф де Вардка.

Үз-үзенә нык ышанган Гасконь егете шундук Сен-Жермендә булган хәлне исенә төшереп, күз алдына китереп алды. Яшен тизлеге белән хатны ачты, Кэттиның бу хәлне күреп кычкырып җибәрүенә дә әһәмият итмәде.

— Ай аллам, нишләвегез бу, әфәндем? — диде кыз.

— Берни дә юк! — диде д'Артаньян һәм хаттагы мондый юлларны укыды:

«Сез минем беренче хатыма җавап бирмәдегез. Ни булды сезгә — авырыйсызмы, әллә де Гиз ханымнардагы балда миңа ничек итеп яратып караганыгызны оныттыгызмы? Сезнең өчен бик җайлы форсат бит бу, граф! Кулыгыздан ычкындырмагыз».

Д'Артаньян агарынып китте; хатта язылганнар егетнең гарьлегенә кагылды; моны ул үзенең мәхәббәтен мыскыл итү дип аңлады.

Кэтти егетне бик кызганган тавыш белән, яңадан аның кулын кысып, әйтә куйды:

— Һай, бичара д'Артаньян әфәндем!

— Мине кызганасыңмыни, ихлас күңелле сеңелкәем?

— Кызганам шул! Чын күңелемнән кызганам! Мин дә бит мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләм!

Д'Артаньян, кызга беренче тапкыр игътибар беләнрәк күз салып:

— Син мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләсеңмени? — дип сорады.

— Бәхетсезлегемә каршы, беләм шул!

— Ул чагында, мине кызганасы урында, син миңа байбикәңнән үч алырга булышыр идең.

— Ә сез аннан ничек итеп үч алмакчы буласыз соң?

— Мин аңа үземнең аңардан көчлерәк булуымны күрсәтеп, көндәшем урынын алыр идем.

— Юк, әфәндем, андый эштә мин сезгә ярдәмче була алмыйм! — дип җәһәт кенә җавап кайтарды Кэтти.

— Нигә? — диде д'Артаньян.

— Ике сәбәбе бар.

— Нинди ике сәбәп?

— Беренчесе шул — минем байбикәм сезне беркайчан да яратмаячак.

— Ә син аны каян беләсең?

— Сез минем байбикәмне бик нык рәнҗеткәнсез.

— Мин?! Ничек рәнҗетим мин аны — танышканнан бирле мин аның колы кебек аягына егылып яшим бит. Зинһар, әйтче әле.

— Мин аны... минем күңелемә күз салырга теләгән кешегә генә әйтәчәкмен.

Д'Артаньян тагын бер тапкыр Кэттига игътибар беләнрәк күз салды. Кыз бик яшь, чибәр иде шул — аның шул чибәрлеге һәм яшьлеге өчен бик күп герцогинялар үзләренең таҗларын да кызганмаслар иде.

— Кэтти, кайчан телисең, шунда күңелеңә күз салырмын, аннан гына эш тормас, сөекле сеңлем,— диде егет һәм кызны чупылдатып үбеп тә алды. Бичара Кэттиның ике бите чия төсле алсуланып китте.

— Юк! Сез мине яратмыйсыз! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды кыз.— Сез байбикәмне генә яратасыз, әле генә үз телегез белән шулай дип әйттегез бит.

— Шуның аркасында икенче сәбәбен әйтмисеңме?

Үзен егет үпкәч һәм аның яратып каравын да күргәч, Кэтти, батыраебрак китеп, икенче сәбәбен дә әйтте:

— Икенче сәбәбе шул, әфәндем,— мәхәббәттә һәркем үзе өчен тырыша,— диде.

Д'Артаньян бары тик хәзер генә кызның моңаеп карап калуларын, алгы бүлмәдә, баскычта, коридорда очрауларын, туры килгән саен кызның кулы белән егеткә орынып китүен, тынын кысып кына авыр сулап куюларын исенә төшерде, бай ханымның күңеленә ошарга тырышам дип, ул субретканы бөтенләй искәрмәгән дә икән: бөркет аулаганда чыпчыкны күрмисең шул.

Әмма бу юлы инде безнең Гасконь егете Кэттиның шундый ихлас беркатлылык белән яисә әрсезлек-тыйнаксызлык белән әйтелгән мәхәббәтеннән нинди файда чыгарып буласын бик тиз төшенеп алды: граф де Вардка дип язылган хатларны кулга төшерергә, миледины күзәткәләп торырга, аның йокы бүлмәсе белән янәшә генә булган Кэтти бүлмәсенә теләсә кайчан керергә мөмкин бит. Күрүебезчә, хыянәтчел егет миледины үз теләге беләнме, я булмаса ирексезләпме үзенеке итәр өчен күңеленнән бичара кызны корбан итеп тә куйды.

— Димәк, Кэтти җаным, син минем үзеңне яратуыма ышанмыйсың, шуны исбат итүемне телисең? — диде ул кызга.

— Ниндиярату турында сөйлисез сез? — дип сорады кыз.

— Сезгә күрсәтергә теләгән яратуым турында.

— Ә сез аны ничек исбат итмәкче буласыз?

— Телисеңме, байбикәң янында буласы вакытымны бүген синең белән үткәрәм.

— Бик, бик телим,— диде Кэтти, кулларын чәбәкләп.

— Теләсәң, кил монда, чибәрем,— диде д'Артаньян, креслога утыра башлап.— Әйтсәм әйтим: минем моңарчы синең кебек сөйкемле, чибәр асрау кыз очратканым юк иде әле.

Бу сүзләрен егет шундый килештереп, оста итеп әйтте, мондый сүзгә бик ышанасы килгән бичара кыз ышанмыйча булдыра алмады... Хәер, д'Артаньянның гаҗәбенә каршы, сөйкемле Кэтти, тиз генә бирешергә теләмичә, беркадәр карышып та маташты.

Берең карыша, икенчең һаман кыса торгач, вакытның узганы сизелми дә икән.

Тәнге сәгать уникене сукты һәм сәгать тавышы белән бергә миледи бүлмәсендә кыңгырау чыңлады.

— Ай аллам! — дип куйды Кэтти.— Мине байбикәм чакыра ич. Бар, кит! Кит тизрәк!

Д'Артаньян, кызның кушканын үтәргә җыенгандай, торып, эшләпәсен алды, ләкин баскычка чыга торган ишекне ачасы урында тиз генә зур шкаф ишеген ачты да милединың күлмәкләре һәм пеньюарлары арасына кереп яшеренде.

— Нишлисез? — дип кычкыра төшеп сорады Кэтти.

Д'Артаньян инде кулына ачкычны алып өлгергән иде — эчтән бикләп алды да эндәшмәде.

— Я! Нишлисез сез анда — йокладыгыз мәллә? Мин чылтыраткач, ник килмисез? — дип кычкырды миледи усал гына итеп.

Д'Артаньян миледи бүлмәсенең ишеге ачылганын ишетте.

— Киләм, миледи, киләм,— дип кычкырды Кэтти, байбикәсенең каршысына йөгереп.

Тегеләр икәүләп йокы бүлмәсенә кереп киттеләр, ишек ачык калды һәм д'Артаньян милединың асравын ничек тиргәгәнен ишетеп торды; ниһаять, ханымның ачуы сүрелде һәм Кэтти аңа булышкан арада д' Артаньян турында сүз чыкты.

— Бүген кич нишләптер безнең Гасконь егете күренмәде,— диде миледи.

— Шулаймыни, ханым, килмәдемени?! — дип гаҗәпләнгән булды Кэтти.— Унышка ирешми торып шулай ташлап китә торган бер җилбәзәк микәнни ул?

— Юк ла! Аны я де Тревиль әфәнде, я Дезэссар әфәнде җибәрмәгәндер. Мин үземнең көчемне беләм, Кэтти; миннән алай ансат кына китә алмас ул.

— Аны нишләтергә уйлыйсыз соң, ханым?

— Нишләтергә уйлыйммы?.. Бер дә борчылма, Кэтти, ул кеше белән минем арада ул үзе дә белмәгән шундый нәрсә бар... Аның аркасында мин кардинал хәзрәтләренең ышанычын югалта яздым. О, мин аннан үчемне алам әле!

— Ә сез аны, ханым, яратасыздыр дип уйлаган идем мин.

— Аны яратам?! Дошманым урынына күрәм мин аны! Лорд Винтерның җанын үз кулында тотып та үтерми калган бер тинтәк ул, шуның аркасында мин өч йөз мең ливр рента югалттым!

— Шулай шул,— диде Кэтти,— сезнең улыгыз — абзасының бердәнбер варисы бит, ул үсеп балигъ булганчы байлык сезнең кулда була иде.

Бу гүзәл җан иясенең д'Артаньян алдында якын итеп, дус итеп сөйләшкән кешесен дуэльдә үтермәгән өчен егетне гаепләвен, чит кешеләр белән сөйләшкәндә зур кыенлык белән генә йомшарта торган усал, кискен тавышын ишеткәч, д'Артаньян бөтенләй калтырана ук башлады.

— Кардинал аны кызганырга кушмаган булса, мин әллә кайчан үч алә идем инде аннан, тик ни өчен кызганырга кушкандыр, белмим,— диде миледи.

— Әйе шул! Аның каруы, ханым, сез аның сөйгәнен — теге яшь кенә галантерейчы хатынын бер дә кызганмадыгыз.

— Ә! Каберчеләр урамындагы кибетче хатынныммы?! Гасконь егете аны күптән онытты инде, дөньяда барлыгын да белми. Чыннан да, бик шәп итеп үч алдым бит!

Д'Артаньянның маңгаена салкын тир бәреп чыкты: чыннан да коточкыч бер әдәми зат иде бу хатын.

Ул тегеләрнең сөйләшүенә колак салып тыңлавында дәвам итсә дә, кызганычка каршы, милединың туалеты тәмам булган иде инде.

— Хәзер инде барыгыз, үз бүлмәгезгә чыгыгыз, мин биргән теге хатка иртәгә җавап алып кайтырга тырышыгыз,— диде миледи.

— Де Вард әфәндегә язган хатыгызгамы? — дип сорады Кэтти.

— Әлбәттә, шуңа, де Вард әфәндегә.

— Миңа, минемчә, ул кеше бичара д'Артаньян әфәндегә бөтенләй дә охшамаган,— дип сөйләнде Кэтти.

— Барыгыз, акыллым, артык күп сөйләшкәнне яратмыйм мин,— диде миледи.

Д'Артаньян шапылдап ишек ябылганны, ике тапкыр шылт-шылт итеп ике бик бикләнгәнен ишетте — миледи эчтән бүлмәсен бикләп алды; Кэтти да, тавышланмаска тырышып кына, ишекне ачкыч белән бикләп куйды; шуннан соң инде д'Артаньян шкаф эченнән чыкты.

— Абау! Сезгә ни булды? Йөзегез ап-ак! — дип пышылдады Кэтти.

— Кабахәт җан! — дип мыгырданды д'Артаньян.

— Акрын! Акрын! Барыгыз, китегез! — диде Кэтти.— Ике бүлмә арасы бик юка, мондагы сүз тегендә ишетелеп тора!

— Шуңа күрә китмим дә,— диде д'Артаньян.

— Ничек — китмисез? — диде Кэтти кызарынып.

— Китсәм дә... соңрак китәм.

Шулай дип, ул Кэттины үзенә таба тартып кочаклап алды; кыз карышса, тавыш кына булачак иде. Шуңа күрә Кэтти карышмады.

Бу — миледига карата булган үч-ачуның тышка бәреп чыгуы иде. Үч алу теләге татлы була диләр, д'Артаньян моның хак сүз икәнлегенә ышанды. Шуңа күрә, йөрәгендә бераз гына мәрхәмәт хисе булса, шушы ирешкән теләге белән ул канәгатьләнеп калыр иде, әмма егетнең йөрәгендә горурлык һәм минминлектән башка тойгы юк иде шул.

Шулай да д'Артаньян — аның егетлегенә басым ясап әйтик — Кэттига булган йогынтысын иң элек кыздан Бонасье ханымның язмышын төпченеп белешүгә файдаланды. Бичара кыз, ул хакта мин берни белмим, чөнки байбикәм миңа барлык серен дә чишеп бетерми, дип тәре каршына басып ант итте, шулай да Бонасье ханымның исән булуын бернинди шикләнүсез әйтте.

Кэтти милединың ни сәбәпле кардиналның ышанычын югалта язуын да белми иде, әмма бу мәсьәләдә д'Артаньян үзе кызга караганда күбрәк белә иде; ул бит үзе Англиядән китеп барган чагында тоткарланган корабларның берсендә миледины күргән иде, шуңа күрә эшнең хикмәте теге асылташ мәсьәләсенә кайтып калганлыгына шикләнми иде.

Әмма аерым-ачыгы шул — лорд Винтерны үтермәгәне өчен д'Артаньянга карата милединың күңелендә гомергә онытмаслык чын нәфрәт уянган иде.

Иртәгәсе көнне д'Артаньян тагын миледи янына барды. Ханымның кәефе бер дә әйбәт түгел иде. Д'Артаньян, моның сәбәбе де Вард әфәндедән җавап хаты булмавыннандыр, дип уйлады. Бүлмәгә Кэтти кергәч, миледи аның белән дә бик коры-кырыс сөйләште. Кэттиның д'Артаньянга төбәлгән карашы: «Менә күрәсезме, сезнең хакка нинди хәлгә төштем мин», дигән мәгънәне аңлата иде.

Шулай да азакка таба гүзәл ана арслан беркадәр йомшый төште, д'Артаньянның аны яратуы турындагы сүзләрен миледи елмаеп тыңлап утырды һәм хәтта кулын да үптерде.

Д'Артаньян аның яныннан чыкканда ни дип уйларга да белмәде, әмма алай юктан гына югалып кала торган егет түгел иде ул, шуңа күрә, миледи янына йөрүдән туктамыйча, күңеленнән кечкенә генә бер план корды.

Ишек төбендә ул Кэттины очратты һәм, кичәге кебек, аның бүлмәсенә менде. Милединың Кэттины бик нык ачуланганын, кушкан йомышын үтәмәгәне өчен шелтәләгәнен белде. Миледи граф де Вардның хатка каршы җавап бирмәвен һич аңлый алмый икән, кызга иртән сәгать тугызда үз бүлмәсенә өченче хатны кереп алырга кушкан.

Д'Артаньян Кэттидан иртәгә иртән әлеге хатны үзенә китерергә сүз бирдертте; бичара кыз сөйгән егете сораганнарның

барысын да эшләргә вәгъдә итте: кызның тәмам башы-күзе әйләнгән иде шул.

Бу юлы да хәл нәкъ кичәге төсле булды: д'Артаньян кыз бүлмәсендәге шкаф эченә кереп бикләнде, миледи Кэттины чакырып алып, туалеты белән шөгыльләнде, аннары Кэттины чыгарып җибәрде дә ишеген бикләп алды. Кичәге шикелле, д'Артаньян бу юлы да өенә иртәнге сәгать биштә генә кайтып керде.

Сәгать унбердә аның янына Кэтти килде: кыз кулына милединың яңа хатын тоткан иде. Бу юлы ул хатны д'Артаньянга берсүзсез бирде; егет ни теләсә, шуны эшләргә ирек куйды; хәзер инде ул үзенең чибәр солдатына җаны-тәне белән бирелгән иде.

Д'Артаньян хатны ачып түбәндәге юлларны укыды:

«Менә мин сезгә үзегезне яратуым турында өченче тапкыр язам инде. Карагыз, сак булыгыз: дүртенче тапкырында, мин сезне дошман күрәм, дип язмагаем.

Әгәр мондый хатагыз өчен үкенә торган булсагыз, шушы хатны сезгә китереп бирүче кыз сезгә тәрбияле кеше ничек итеп миннән үзенең гаебен йолдырырга тиешлеген әйтер».

Д'Артаньян хатны укыган чагында бер агарды, бер кызарды.

Егетнең йөзеннән күзен алмый карап торган Кэтти:

— О, сез аны һаман яратасыз икән! — дип әйтеп куйды.

— Юк, Кэтти, ялгышасың, хәзер мин аны яратмыйм инде, әмма үземне кимсеткәне өчен мин аңардан үч алырга телим.

— Әйе, сезнең ничек итеп үч аласыгызны беләм мин, ул турыда миңа әйттегез инде.

— Сиңа барыбер түгелмени соң, Кэтти? Минем бары тик сине генә ратканымны беләсең ич.

— Аны белеп буламыни?

— Менә минем аңардан ничек итеп үч алганымны күргәч белерсең.

Кэтти авыр сулап куйды.

Д'Артаньян каурый каләм алды да болай дип хат язды:

«Ханым, сезнең баштагы ике хатыгызның миңа атап язылган икәнлегенә мин моңарчы ышанмаган идем, чөнки үземне андый илтифатка лаекмындыр дип санамый идем; өстәвенә, мин бик авырый идем, шул сәбәпле сезнең хатыгызга барыбер җавап бирә алмаган булыр идем.

Әмма бүген мин сезнең ягымлы илтифатыгызга ышанырга тиеш булам, чөнки сезнең хатыгыз гына түгел, асравыгыз да минем сезнең мәхәббәтегезгә лаек булу бәхетенә ирешүемне раслап тора.

Асравыгызның тәрбияле кеше ничек итеп үзенең гаебен йолдырырга тиешлегенә мине өйрәтәсе юк. Шулай итеп, бүген сәгать унбердә сездән гаебемне кичерүегезне сорап үзем килә-

чәкмен. Килүемне бер генә көнгә кичектерү дә, минемчә, сезгә карата яңадан илтифатсызлык күрсәтү булыр иде.

Сезнең тарафтан дөньяда иң бәхетле ителгән бәндәгез,

*граф де Вард».*

Иң элек бу хат ялган хат иде; аннары, шактый тупас язылган иде ул, безнең замандагы әдәп-әхлак кагыйдәләреннән чыгып караганда, бу — хатын-кызны кимсетә торган хат иде, ләкин ул заман кешеләре хәзерге кебек алай артык нечкәрмәгәннәр. Өстәвенә д'Артаньян милединың моннан зуррак эшләрдә дә хыянәт кылырга сәләтле бер хатын икәнлеген аның үз авызыннан ишетеп белә, шуңа күрә егетнең аңа ихтирамы да бик чамалы иде. Әмма, шуңа да карамастан, ниндидер бер сукыр теләк аны һаман шул хатынга омтылдыра,— ханымга кешe буларак түбәнсетеп карау тойгысы белән кушылган булса да, ул — каннарны уйната торган тыелгысыз бер теләк, әйтергә ярaса, хатынның кочагына керәсе килү теләге иде.

Д'Артаньянның планы бик гади: Кэтти бүлмәсеннән аның байбикәсе бүлмәсенә барып керергә дә, шул чагында ханымның гаҗәпләнү, аптырау, оялу һәм куркуыннан файдаланып, аны кулга төшерергә иде; ихтимал, егетнең бу нияте барып чыкмавы да мөмкин, әмма... тәвәккәлләмәсәң, бернигә дә ирешеп булмый бит. Тагын бер атнадан кампания башланачак, егеткә анда китәргә туры киләчәк, кыскасы, д'Артаньянның мәхәббәт идиллиясе уйнап маташырга вакыты да юк иде.

— Мә, миледига тапшыр бу хатны: де Вард әфәнденең җавабы булыр бу,— диде егет, конвертка салып ябыштырган хатны Кэттига тоттырып.

Бичара Кэтти көл төсле агарынып китте: хатта ниләр язылганлыгын белеп тора иде ул.

— Карале, җаным,— диде аңа д'Артаньян,— бу хәлнең тегеләйме-болаймы булып бетәргә тиешлеген үзең дә беләсең бит инде. Беренче хатны син графның хезмәтчесенә түгел, бәлки минем хезмәтчегә биргәнлегенне, де Вард укыйсы башка хатларны да мин ачып укыганны милединың белеп алуы да ихтимал бит. Шуннан соң инде ул сине йортыннан куып чыгарачак, ә бит син ул хатынның үч алу мәсьәләсендә моның белән генә чикләнеп калмавын бик яхшы беләсең.

— Беләм шул! Ә кем хакына эшләдем соң мин боларны? — диде Кэтти.

— Минем хакка, анысын мин бик яхшы беләм, чибәрем, һәм, ихластыр, моның өчен чын күңелемнән бик зур рәхмәт сиңа! — диде егет.

— Хатыгызга ниләр яздыгыз соң?

— Анысын миледи үзе әйтер сиңа.

— О, сез мине яратмыйсыз, бәхетсез мин! — дип кычкырып әйтеп куйды Кэтти.

Мондый шелтәгә каршы хатын-кызны алдый торган бер

генә җавап бар. Д'Артаньян кызга шундый оста итеп җавап бирде — Кэттиның сүзе дөреслектән бик ерак булып калды.

Шулай да ул шактый озак елаганнан соң гына хатны миледига тапшырырга риза булды, д'Артаньянга исә кызның әнә шул эшкә риза булуы гына кирәк тә иде.

Өстәвенә егет кызга, байбикәң яныннан иртәрәк чыгып, синең яныңа керермен, дигән вәгъдәсен дә әйтте.

Мондый сүзне ишеткәч инде бичара Кэттиның күңеле тәмам тынычланды.

## IV

## *АРАМИС БЕЛӘН ПОРТОСНЫҢ ГАСКӘРИ КИРӘК-ЯРАК ЮНӘТҮЛӘРЕ*

Гаскәри кирәк-ярак юнәтү мәшәкатенә керешеп киткәннән бирле дүрт дус әледән-әле бергә җыела алмый башлаганнар иде. Һәркайсы, аерым-аерым, кайда туры килсә, дөресрәге — кайда җае чыкса, шунда тамак туйдыра. Бик тиз уза торган бу кадерле вакытның бер өлешен гаскәри хезмәт ала. Шулай да алар атнага бер тапкыр, көндезге сәгать берләр тирәсендә Атос квартирында очрашырга дип сүз куешканнар иде, чөнки Атос, үзенең антына һаман тугры булып, өеннән беркая да чыкмый иде.

Д'Артаньян янына Кэтти килгән көн нәкъ дусларның бергә җыеласы көне иде.

Кэтти чыгып китү белән, д'Артаньян Феру урамына юл тотты.

Ул килеп кергәндә Атос белән Арамис фәлсәфи әңгәмә корып утыралар иде. Арамис яңадан рухани булып китү турында уйлана. Атос, гадәтенчә, аның бу уена каршы килми, шулай ук аны хупламый да. Ул һәркемнең үз ирке дигән фикердә тора. Киңәшләрен дә бик үтенеп сорасалар гына әйтә иде:

— Кешеләр гадәттә киңәш сорасалар да аны үтәмәс өчен генә сорыйлар, берәрсе инде ул киңәшне тота икән, соңыннан әлеге киңәшнең нәтиҗәсенә сине гаепле итәр өчен генә эшли аны,— ди Атос.

Д'Артаньян артыннан Портос та килеп керде. Шулай итеп, дүрт дус җыелышып беттеләр.

Дүртесенең чырае дүрт төсле иде: Портосның йөзе тыныч, д'Артаньянның чыраенда — өмет, Арамисныкында — борчу, Атосныкында — гамьсезлек галәмәтләре сизелеп тора иде.

Бераз гына сөйләшеп, Портос дәрәҗәле генә бер ханымның үзен кыен хәлдән коткарырга теләгәнлеген сиздереп өлгерүгә, Мушкетон килеп җитте.

Портосны өйгә чакыра килгән иде ул, шактый ризасыз бер төс белән әйтүенә караганда, хуҗа әфәндесе бик ашыгыч кирәк икән.

— Минем тегė кирәк-ярак мәсьәләсендәме әллә? — дип сорады Портос.

— Әйе дә, түгел дә,— диде Мушкетон.

— Миңа дөресен генә әйтә алмыйсызмыни?..

— Әйдәгез әле, әфәндем, әйдәгез.

Портос урыныннан кузгалып, дуслары белән суабуллашты да Мушкетон артыннан чыгып китте.

Тагы бераздан ишектә Базен күренде.

— Ни кирәк, дустым? — дип ягымлы-йомшак тавыш белән сорады Арамис — күңеле дингә таба тартылган саен аның тавышы да шулай йомшарып-ягымлыланып китә иде.

— Әфәндем, сезне өйдә бер кеше көтеп тора,— диде Базен.

— Бер кеше?! Нинди кеше?

— Нindидер бер хәерче.

— Сез аңа, Базен, хәер садакасы бирегез дә, алланың бер гөнаһлы бәндәсе өчен дога кылыгыз, дип әйтеп, чыгарып җибәрегез.

— Ул хәерче сезне күреп сөйләшмичә китмим, ди, мине күрү аның өчен зур сөенеч булыр, ди.

— Миңа берәр нәрсә әйтергә кушмадымы соң ул?

— Кушты. «Әгәр дә Арамис әфәнде өенә кайтып минем белән күрешергә теләмәсә, әйтегез үзенә: мин Турдан килдем», диде.

— Турдан! — дип кычкырып җибәрде Арамис.— Әфәнделәр, берүк гафу итә күрегез, минемчә, ул кеше мин көткән хәбәрләрне китергән булырга тиеш.

Шулай дигәч, Арамис сикереп торды да ашыга-ашыга чыгып та китте.

Атос белән д'Артаньян икәү генә калдылар.

— Бу егетләр эшләрен җайладылар бугай,— ничек уйлыйсыз, д'Артаньян? — дип сорады Атос.

— Белүемчә, Портосның эшләре бик әйбәт бара,— диде д'Артаньян.— Арамиска килсәк, дөресен генә әйткәндә, аның өчен минем чынлап торып борчылганым да юк, ә менә сез, Атос дус... Сез үзегезгә тиешле хәләл пистольләрегезне бик юмартланып инглизләргә өләштегез дә менә хәзер нишләрсез икән инде?

— Шул маңка малайны үтергәнемә бик сөенәм мин, дустым, чөнки инглизне үтерү — изге эш ул, ләкин аның акчасын кесәгә алып салу минем өчен гафу ителмәслек бер эш булыр иде.

— Юкны сөйләмәгез инде, Атос дус! Валлаһи, фикер йөртүегез әллә ничек гаҗәп-сәер сезнең.

— Я, ярый, анысын куеп торыйк. Кичә минем янга де Тревиль әфәнде килеп киткән иде, ул әйтте: сез кардинал химаясендәге нindидер шикле инглизләр янына еш кына барып йөрисез икән,— дөресме шул?

— Бер инглиз хатыны янына барып йөрүем дөрес — ул ханым турында мин сезгә әйткән идем инде.

— Ә, әйе, аксыл-сары чәчле хатын; ул ханым турында мин сезгә кайбер киңәшләр дә әйткән идем, тик әйтүем бушка гына булган, чөнки сез минем ул киңәшләремне тотмагансыз.

— Мин үземнең дәлилләремне әйткән идем бит.

— Әйе, әйе. Үзегезгә кирәк-ярак юнәтергә ярдәме тиячәк дигән идегез бугай.

— Димәгән кая! Мин ул хатынның Бонасье ханымны урлауга катнашканлыгын белдем.

— Аңлыйм. Бер хатынны эзләп табу өчен, икенче хатын тирәсендә чуаласың: бик урау юл булса да — иң күңелле юл.

Д'Артаньян Атоска барысын да сөйләп бирәм дигәндә генә тыелып калды: намус-абруй мәсьәләсендә Атос артык таләпчән бер кеше иде шул, ә безнең гашыйк егетнең миледига каршы корган планындагы кайбер детальләрне безнең пуританыбыз башта ук кире кагар иде,— монысына инде д'Артаньян бер дә шикләнми иде; шул сәбәпле ул әлеге серләрен дустына сөйләмәскә булды, ә Атос андый серләр белән бөтенләй кызыксынмаганлыктан, д'Артаньянның да ихласлыгы шул чамадан артмады.

Шулай итеп, без бер-берсенә әллә ни сер сөйләргә җыенмаган ике дусны калдырып торып, Арамис артыннан китик.

Без ул егетнең үзен күреп сөйләшергә теләүче кешенең Турдан килгән икәнлеген ишеткәч тә тиз генә Базен артыннан йөгерүен, дөресрәге — аны узып та китүен күреп калган идек инде; Феру урамы белән Вожирар урамы арасын ул бер-ике генә сикерде.

Өенә кайтып кергәндә, анда аны чыннан да бик сәләмә киемле, тәбәнәк буйлы, акыллы гына карашлы бер кеше көтеп тора иде.

— Мине сез сораган идегезме? — диде мушкетер.

— Мин Арамис әфәндене сораган идем. Сезме ул?

— Нәкъ үзе булам. Сезнең миңа тапшырасы әйберегез бармы?

— Әйе, бер чиккән яулык күрсәтсәгез.

— Менә ул,— диде Арамис, эчке кесәсеннән ачкыч алып, кара агачтан кабырчыклар ябыштырып эшләгән кечкенә генә тартманы ача-ача.— Менә ул, карагыз.

— Яхшы, хезмәтчегез чыгып торсын,— диде хәерче.

Чыннан да Базен, хуҗа әфәндесенең бу хәерчегә ни өчен кирәк булуын бик беләсе килеп, Арамис артыннан өйгә аның белән бергә диярлек килеп кергән иде, тик андый җитезлегенең әллә ни файдасы булмады; хәерче әлеге сүзен әйтүгә, хуҗа әфәндесе Базенга ымлап кына чыгып китәргә кушты да Базен моңа буйсынырга тиеш булды.

Ул чыгып китүгә, хәерче, безне күреп-тыңлап торучы юкмы дигәндәй, як-ягына тиз генә күз йөрткәләп алды, килешсез

генә итеп каеш белән буып куйган сәләмәсен чишеп җибәрде һәм шуннан соң камзулының өске өлешен шытырдатып сүтте дә аннан хат чыгарды.

Арамис, хатның печатен күргәч, шатлыгыннан кычкырып ук җибәрде, тышындагы язуын үбеп алды һәм илаһи бер нәрсә тоткан кебек калтырана-калтырана хатны ачып укырга керешге. Хатта болай дип язылган иде:

«Дустым, тәкъдир безгә тагын беркадәр вакыт кавышмый яшәргә язган булса да, гүзәл яшьлегебез көннәре бөтенләйгә китеп югалмаган әле. Лагерьда үзегезнең вазифагызны үти торыгыз, мин үз вазифамны башка җирдә үтим. Шушы хатны тапшыручы кеше биргән әйберне кабул итеп алыгыз, солтанатлы, батыр дворяннарча сугышыгыз һәм мине онытмагыз. Кара күзләрегезне үбеп калам.

Хушыгыз, дөресрәге — сау булып торыгыз!»

Ул арада теге хәерче камзул эчен сүтә торды; шакшы сәләмәләре эченнән ашыкмыйча гына ике бәрабәрле йөз илле испан пистоле чыгарып, өстәл өстенә тезеп салды, аннары ишекне ачып, баш иде дә, бу хәлгә шаккатып карап торган Арамис берәр сүз әйтеп өлгергәнче, чыгып та китте.

Шуннан соң егет хатны тагын бер кабат укып чыкты һәм азагында өстәп куелган мондый җөмлә дә барлыгын күрде:

«P. S. Бу хатны тапшыручы кеше — граф һәм испан гранды, аны яхшы кабул итегез».

— О, алтын хыяллар! — дип кычкырып әйтеп куйды Арамис.— Дөнья матур, әйе, шулай! Без яшь әле, әйе, шулай! Безнең бәхетле көннәр алда әле, әйе, шулай! Мәхәббәтем дә, каным да, җаным да, бөтен-бөтенесе бер синең өчен, фәкать синең өчен генә, гүзәл җанашым!

Шулай дип, ул, өстәл өстендә ялтырап яткан алтын тәнкәләрне дә күрмичә, хисләнеп хатны үбәргә керешге.

Базен кыяр-кыймас кына ишекне шакыды; Арамиска аны тышта тотарлык сәбәп калмаган иде инде, шуңа күрә хезмәтчесенә керергә рөхсәт итте.

Алтын тәңкәләрне күргәч, Базен исе китеп шаккатып калды, д'Артаньян килгәнлеген әйтергә дип керүен дә онытты. Гасконь егете исә, Атос яныннан чыккач, теге хәерче дигәннәренең ниндирәк кеше икәнлеген күрәсе килеп, Арамис янына да кереп чыгасы иткән иде.

Ләкин ул үзе хакында Базенның онытуын күреп, Арамис каршында әллә ни тәкәллеф саклап тормастан, килүе турында үзе хәбәр итте.

— Оһо! Шайтан алгыры! — дип куйды д'Артаньян.— Бу сливаларны, Арамис дус, сезгә Турдан җибәргән булсалар, боларны үстергән бакчачыга, зинһар, минем искиткеч соклануымны әйтеп рәхмәтемне тапшырыгыз.

— Ялгышасыз, дустым,— диде Арамис, гадәтенчә серен яшереп,— сәяхәтебез вакытында ук бер иҗекле сүзләр белән

яза башлаган теге поэмам өчен наширем мина гонорар җибәргән.

— Һе, алай икән! — диде д'Артаньян.— Наширегез бик юмарт кеше икән, Арамис дус. Әйтәсе сүзем менә шул.

— Ничек ул, әфәндем?! — дип кычкыра салды Базен.— Поэма өчен дә шул хәтле акча түлиләрмени?! Булмас ла! И әфәндем, алайса сез бөтен теләгәнегезне эшли аласыз. Сез бит де Буатюр әфәнде, я булмаса де Бенсерад әфәнде шикелле үк атаклы бер кеше булып китә аласыз. Бу да бик ошый миңа. Шагыйрь кеше ул аббаттан чак кына кайтышрак. Һай, Арамис әфәнде, зинһар, шагыйрь булып кына китегез.

— Базен, минемчә, сез сүзгә кысыла башладыгыз, дустым,— диде Арамис.

Базен, гаебен аңлап, башын иде дә бүлмәдән чыгып китте.

— Алай икән, алай икән,— дип сөйләнде д'Артаньян елмаеп.— Поэмаларыгызны алтын бәрабәренә сатасыз икән — болай булгач, эшләрегез бик әйбәт инде, дустым. Тик саграк булырга кирәклеген генә онытып җибәрмәгез, хатыгызны төшереп калдыра күрмәгез — әнә кесәгездән чыгып тора. Ул хат та наширегездән килгәндер.

Арамис кып-кызыл булып кызарынып китте, хатны эчкәрәк тыкты да камзулын каптырып куйды.

— Д'Артаньян,— диде аннары,— әйдәгез дусларыбыз янына киттек. Мин хәзер бай; сезгә дә баерга чират җиткәнче теге уртак мәҗлесләрне яңартып җибәрик.

— Бик ризамын! — диде д'Артаньян.— Бик күптән җүнле сый күргән юк инде безнең. Өстәвенә минем бүген кич шактый хәтәр бер эш башкарасым да бар, шуна күрә берничә шешә иске бургунд шәрабы эчеп, бераз батырая төшүгә дә каршы түгелмен.

— Иске бургунд шәрабына да ризамын. Минем дә беркинди каршылыгым юк,— диде Арамис. Алтын тәңкәләрне күргәч, аның руханилыкка китү турындагы уйлары юып алгандай юкка чыккан иде.

Кирәккә тотарга дип кесәсенә өчме-дүртме пистоль салгач, калганнарын теге тылсымлы бер нәрсә итеп тота торган таныш кульяулык янына, перламутр тышлы кара тартмага салып бикләп куйды.

Иң элек ике дус Атос янына киттеләр; Атос, өемнән беркая чыкмыйм дигән антына тугрылык саклап, аш-суны үзенең өенә китертү шарты белән, табын оештыру мәсьәләсенә керешге; д'Артаньян белән Арамис, аның аш-сый мәсьәләсендә бик зур белгеч икәнлеген истә тотып, бу мөһим эшнең бөтен мәшәкатьләрен, бик риза булып, Атос карамагына тапшырдылар.

Портос янына барырга чыккач, Бак урамы чатында аларга Мушкетон очрады. Портосның хезмәтчесе, бик күңелсез кыяфәттә, бер качыр белән бер ат куалап килә иде.

Д'Артаньян бик гаҗәпләнгән дә, беркадәр сөенгән дә сыман итеп кычкырып әйтеп куйды:

— Бу минем теге сары айгыр ич! Арамис, бу атка карагыз әле! — диде.

— Ай, нинди коточкыч ат аламасы! — диде Арамис.

— Алайса, әйтсәм әйтим, дустым: Парижга килгәндә мин шушы атка атланып килгән идем инде,— диде д'Артаньян.

— Ничек ул алай, әфәндем, сез бу атны беләсезмени? — диде Мушкетон гаҗәпләнеп.

— Бу атның төсе үзенә бер төрле икән. Мондыйны гомеремдә беренче тапкыр күрәм,— дип куйды Арамис.

— Әйе шул! — диде д'Артаньян сөенеп.— Саткан чакта миңа аның төсе өчен генә өч экю бирделәр. Калган ягы өчен, әлбәттә, унсигез ливр да бирмәсләр иде. Шулай да, Мушкетон, бу ат ничек синең кулга килеп эләкте соң әле?

— Һай, әфәндем, ичмасам, сорамагыз, безнең герцогиняның ире маташтырды моны!

— Ничек ул алай, Мушкетон?

— Беләсезме, бер бай ханым безгә бик яхшы мөнәсәбәт күрсәтә, герцогиня де... Хәер, гафу итегез! Хуҗа әфәндем ул ханымның исемен әйтергә кушмады. Безгә шул ханымнан беркадәр бүләк сыман нәрсә — искиткеч шәп испан байталы белән Андалузи качыры алырга туры килде — качыры инде менә сокланып карап туймаслык иде. Ханымның ире моны белеп алган да шул бер дигән малларны безгә китергәндә, кире бордырып, алар урынына шушы хайван аламаларын җибәрткән!

— Син хәзер боларны кире илтәсеңме инде? — дип сорады д'Артаньян.

— Нәкъ шулай,— диде Мушкетон.— Үзегез уйлап карагыз, вәгъдә ителгән атлар урынына боларны ала алмыйбыз бит инде.

— Әлбәттә, шулай; ах, шайтан алгыры, Портосның минем кола айгырга атланганын бик күрәсем килгән иде килүен дә; үземнең Парижга килгән чакта ниндирәк кыяфәттә булуымны күз алдыма китерә алган булыр идем. Ярый, Мушкетон, без сине тоткарлап тормыйбыз инде, бар, хуҗа әфәндеңнең кушканын үтә. Үзе өйдәме соң?

— Өйдә, әфәндем, тик яман да ачулы, үзегез беләсез! — диде Мушкетон.

Шуннан соң ул Бөек Августинлылар яр буена таба китеп барды, ә ике дус беркатлы Портосның ишеге төбенә килеп, кыңгыравын чыңлаттылар. Тик Портос аларның ишегалды аша узганын күреп калган иде, ишекне ачмады. Тегеләрнең кабат-кабат чыңлатуларының да файдасы булмады.

Ул арада Мушкетон, әлеге ат белән качырны куып бара биреп, Яңа күперне узды да Аю урамына килеп җитте. Шунда, хуҗа әфәндесе кушканча, ат белән качырны прокурор йортының ишек тукылдаткычына бәйләде дә, аларны ходай кулына

тапшырып, хуҗа әфәндесе катына кайтып китте һәм аның кушканы үтәлгәнлеген әйтте.

Иртәдән бирле берни ашамаган бичара хайваннар беркадәр вакыттан соң ишек тукылдаткычын тарткалап шундый тавышланырга тотындылар — прокурор кече писеренә, урамга чыгып, күршеләрдән әлеге ат белән качырның кемнеке икәнлеген белешергә кушты.

Кокнар ханым үзенең бүләген күрү белән үк таныды, баштарак боларның ни өчен кире кайтарылуын аңламыйчарак торды, әмма бераздан Портос үзе килеп чыккач, барысы да аңлашылды. Мушкетерның күзләрендә ялтыраган усал ачу чаткылары, егетнең тыелып калырга тырышуына да карамастан, нечкә күңелле сөяркәсенең котын алды. Болай булуның сәбәбе шул: Мушкетон, д'Артаньян белән Арамисны очратуын хуҗа әфәндесеннән яшермичә, әлеге сары атның д'Артаньян Парижга атланып килгән Беарн айгыры икәнлеген, д'Артаньян шуны өч экю акчага саткан булганлыгын сөйләп биргән иде.

Портос, прокурор хатыны белән Сен-Маглуар монастыре янында күрешербез дип сүз куешкач, саубуллашып, китә башлады. Прокурор, аның китүен күреп, егетне ашка утырырга чакырды, ләкин мушкетер бу чакыруны мәгърурана бер төс белән кире какты.

Кокнар ханым, эчтән калтырана-калтырана гына, Сен-Маглуар монастыре янына килде. Монда үзенә үпкә-шелтә сүзләре әйтеләчәген ул алдан ук белеп-сизеп тора иде, әмма Портосның югары җәмгыятькә хас манерлары каршы торып булмаслык бер көч кебек тәэсир итте ханымга.

Үзен мыскыл ителгән дип санаучы ир кеше хатын-кызга нинди каһәр-каргыш, үпкә-шелтәләрен әйтә алса, Портос та башын иеп торган сөяркәсенә шундый сүзләр яудырды.

— И аллам! — диде ханым.— Хәлемнән килердәйнең барысын да эшләдем бит инде мин. Безнең бер клиентыбыз ат белән сату итә. Шул кеше конторга акча түләргә тиеш иде дә бурычын түлисе килми. Мин әлеге качыр белән атны аның бурычы исәбенә алдым. Ул миңа король үзе атланып йөрерлек атлар вәгъдә иткән иде.

— Әйтсәм әйтим, ханым, әгәр ул барышникның сезгә түлисе бурычы биш экюдан артык булса, просто бер карак ул,— диде Портос.

— Арзанракны юнәтү бераүгә дә тыелмый бит, Портос әфәнде,— диде прокурор хатыны акланырга теләп.

— Анысы дөрес, ханым, ләкин арзанракны юнәтергә тырышучы кеше башкаларга юмартрак дуслар эзләргә дә рөхсәт итәргә тиеш.

Шулай дигәч, Портос, борылып, китәргә җыена башлады.

— Портос әфәнде! Портос әфәнде! — дип кычкыра төшеп эндәште прокурор хатыны.— Дөресен әйтим, мин гаепле мон-

да. Сезнең кебек чибәр егеткә гаскәри кирәк-ярак юнәткәндә мин алай сатулашып торырга тиеш түгел идем, билгеле!

Портос, эндәшмәстән, тагын бер адым китә төште.

Шул чагында прокурор хатынына Портосны ниндидер бер нурлы болыт урап алган да бер көтү герцогиня һәм маркизалар аның аяк астына янчык-янчык алтын тәңкә ташлыйлар кебек тоелды.

— Туктагыз әле, Портос әфәнде,— дип кычкырды ханым,— Алла хакы өчен, туктагыз әле, сөйләшәсе сүзебез бар.

— Сезнең белән сөйләшү миңа бәхетсезлектән башка нәрсә китерми,— диде Портос.

— Нәрсәләр кирәк соң сезгә? — Әйтегез.

— Бер нәрсә дә кирәкми, чөнки сездән сорадың ни, сорамадың ни — барыбер.

Прокурор хатыны Портосның беләгенә килеп асылынды да ачы кайгысыннан әйтә куйды:

— Һай, Портос әфәнде, мин андый эшнең бер нәрсәсен дә төшенмим шул. Мин атның нәрсә икәнен беләммени? Ат дирбиясенең нәрсә икәнен беләмме?!

— Шулай булгач, ул эшне миңа тапшырырга иде, ханым, белә торган кешегә. Ләкин сез бит акчаны азрак чыгарырга, арзангарак юнәтергә тырыштыгыз.

— Анысы минем хатам булган, Портос әфәнде, мин аны төзәтәм, ант әгәр, төзәтәм.

— Ничек итеп? — диде мушкетер.

— Тыңлагыз әле. Бүген кич Кокнар әфәнде герцог де Шон янына китә,— ул аны киңәшкә чакырган. Кокнар әфәнде анда ике сәгатьтән дә ким йөрмәячәк. Килегез, үзебез генә булырбыз, үзебезгә кирәк нәрсәләрне исәпләп-санап чыгарырбыз.

— Хәерле сәгатьтә алайса, сөеклем! Менә бусы эш, ичмасам!

— Сез мине кичерәсезме соң инде?

— Карарбыз,— диде Портос, мәгърур бер төс белән.

Һәм алар бер-бере белән «кичкә чаклы» дип саубуллаштылар да аерылышып китеп бардылар.

«Ах, шайтан алгыры! Бу юлы инде метр Кокнарның сандыгын ачармын ахры!» — дип уйлана-уйлана кайтып китте Портос.

## V

## *КАРАҢГЫДА БӨТЕН МӘЧЕ ДӘ СОРЫ БУЛЫП КҮРЕНӘ*

Ниһаять, Портос та, д'Артаньян да түземсезләнеп көткән кич килеп җитте.

Д'Артаньян миледи янына гадәтенчә сәгать тугызлар тирәсендә барды. Ул килеп кергәндә милединың кәефе бик шәп иде; егетне беркайчан да бу кадәр ачык чырай белән каршы

алганы юк иде әле аның. Безнең Гасконь егете теге хатының миледига тапшырылган һәм бик әйбәт тәэсире булганлыгын шундук төшенеп алды.

Бүлмәгә Кэтти килеп керде, ширбәт китерде. Байбикәсе кызга ягымлы, мөлаем карап, бик матур итеп елмаеп куйды, тик бичара кызның чырае бик кайгылы иде — хәтта милединың үзенә илтифат күрсәтүен дә сизмәде шикелле.

Д'Артаньян, бу ике хатынның әле берсенә, әле икенчесенә күз салгалый торгач, күңеленнән: «Табигать боларны тудырганда хаталык кылган: бай ханымны сатлык һәм түбән җанлы иткән, ә субреткага герцогиня йөрәге биргән»,— дип уйлап куйды.

Сәгать ун җиткәндә миледи борчылу галәмәтләре сиздерә башлады. Д'Артаньян монысын да аңлады; ханым әле сәгатькә карап ала, әле урыныннан тора да кире утыра һәм д'Артаньянга: «Сез, әлбәттә, бик әйбәт егет, ләкин өегезгә кайтып китсәгез, тагы да әйбәтрәк булыр идегез!» — дигән сыман елмаеп карый иде.

Д'Артаньян, китәргә кузгалып, кулына эшләпәсен алды; миледи үптерергә дип кулын сузды; каты итеп аның кулын кысты һәм егет милединың болай итүен мутланудан түгел, бәлки китүе өчен рәхмәт белдерүе икәнлеген төшенде.

Д'Артаньян:

— Үлеп ярата икән аны,— дип пышылдап кына сөйләнеп куйды да чыгып китте.

Бу юлы инде аның каршысына Кэтти очрамады — кыз алгы бүлмәдә дә, коридорда да, капка төбендә дә күренмәде. Д'Артаньянга баскыч белән кечкенә бүлмәне үзенә эзләп табарга туры килде.

Кэтти үзенең бүлмәсендә куллары белән битен каплап елап утыра иде.

Д'Артаньянның кергәнен ишетсә дә, башын күтәреп карамады; егет аның янына килеп, кулларыннан тотты; шуннан соң инде кыз үксеп үк җибәрде.

Д'Артаньян уйлаганча, миледи, теге хатны алгач, шатлыгыннан асравына барысын да сөйләп биргән; аннары бу юлы йомышын җиренә җиткереп үтәгәне өчен кызга янчык белән акча да бүләк иткән иде.

Кэтти, бүлмәсенә кайтып керү белән, янчыкны бер почмакка ташлаган, янчык ачык килеш шунда ята, келәмдә, янчык янында, өчме-дүртме алтын тәңкә дә ялтырап күренә иде.

Д'Артаньянның яратып кагылуына җавап итеп кыз башын күтәрде. Аның кыяфәтен күргәч, хәтта д'Артаньян да куркып китте; кыз ялварган-инәлгән бер төс белән егеткә таба кулларын сузды, ләкин авызын ачып сүз әйтергә батырчылык итмәде.

Д'Артаньянның йөрәге хис-тойгыларга әллә ни артык бирелмәсә дә, кызның сүзсез кайгысы аның да күңелен кузгат-

ты: әмма егетнең үз планнарыннан, бигрәк тә соңгы планыннан чигенеп, алдан ук уйлап куйган гамәлләрен үзгәртергә исәбе юк иде. Шуңа күрә ул Кэттига үзен ниятеннән кире кайтарырлык бернинди өметкә юл куймады, ә үзенең бу гамәлен кызга гади бер үч алу итеп кенә күрсәтергә тырышты.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китик: егетнең бу гамәлен чынга ашыру шартлары миледи ярдәме белән шактый җиңеләя дә төште — хатын, битендәге иннек-кершәннәрен могъшукына күрсәтмәскә теләптер, күрәсең, Кэттига йорт эчендәге барлык лампаларны, хәтта йокы бүлмәсендәгене дә сүндерергә кушкан иде. Де Вард әфәнде яктырганчы ук, дөм-караңгыда кайтып китәргә тиеш иде.

Бераздан болар милединың йокы бүлмәсенә кергәнен ишеттеләр. Д'Артаньян тиз генә шкафка кереп посты. Ул кереп кенә өлгерде — кыңгырау да чыңлады.

Кэтти, ишекне ябып, байбикәсе янына кереп китте. Ике арадагы бүлем тактасы бик юка, шуңа күрә ике хатынның сөйләшкән бөтен сүзләре диярлек бу якка ишетелеп тора иде.

Милединың шатлыгы эченә сыймый; ул Кэттидан асравының де Вард белән чынлыкта булмаган очрашуын җентекләбрәк кабат-кабат сөйләтә, граф хатны ничегрәк итеп алды, ни рәвешле җавап язды, чырае нинди иде, чын-чыннан гашыйк булганлыгы сизелеп тора идеме? — дип сораштыра, һәм тынычсабыр күренергә мәҗбүр булган бичара Кэтти өзек-төтек тавыш белән генә җавап кайтара, кызның ямансылавын миледи бөтенләй сизми,— бәхетлеләрнең кеше хәлендә эшләре булмый шул.

Графның килер вакыты якынлаша бара иде, шуңа күрә миледи чыннан да Кэттидан йокы бүлмәсендәге лампаны сүндертте, де Вард килү белән аны үзе янына кертергә кушты.

Кэттига исә моны озак көтәргә туры килмәде. Д'Артаньян, шкафтагы йозак тишегеннән бөтен йорт эче караңгыланып калганлыгын күрү белән, качкан җиреннән йөгереп чыкты; нәкъ шул вакытны Кэтти үз бүлмәсеннән милединың йокы бүлмәсенә керә торган ишекне ябып чыгып килә иде.

— Нинди тавыш ул анда? — дип сорады миледи.

— Мин ул, мин, граф де Вард,— дип тавыш бирде д'Артаньян әкрен генә.

— Ай алла! Үзенең әйткән вакытын да көтмәгән! — дип сөйләнде Кэтти.

— Ни булды? Ник керми ул? — дип калтыранган тавыш белән сорады миледи. Аннары: — Граф, граф, минем сезне көткәнемне беләсез бит,— диде.

Д'Артаньян, шушы чакыруны ишетеп, Кэттины иплəп кенә бер читкәрәк этәрде дә атылып йокы бүлмәсенә кереп китте.

Үзен бәхетле көндәше урынына куеп, аңа дип әйтелгән сөю сүзләрен тыңлап торучы гашыйк егетнең җанын телгәләгән әрнешле гарьлек газабыннан да авыррак газап юктыр дөньяда.

Д'Артаньян мондый газапка эләгәсен уена да китермәгән иде; көнчелек тойгысы аның бәгырен телгәли, шушы минутта күрше бүлмәдә елап утырган бичара Кэтти шикелле үк диярлек, ул да газап утында яна иде.

— Әйе, граф, әйе, сөелүемә бик бәхетле мин,— дип иң йомшак, иң мөлаем тавышы белән сөйләнде миледи, егетнең кулын йомшак кына кысып,— сезнең сөюегезне мин очрашкан саен күз карашыгыздан һәм сүзләрегездән сизеп тора идем. Мин дә сезне сөям. О, иртәгә, иртәгә мин сездән минем хакта уйлавыгызны раслый торган берәр нәрсә алыр идем. Менә, мәгез алыгыз моны — мине онытмас өчен.

Шулай дигәч, миледи бармагыннан йөзеген салып, д'Артаньянга бирде.

Д'Артаньян бу йөзекне милединың кулында күргән булуын исенә төшерде: алмаз кысалы бик матур зәңгәр якут иде ул.

Д'Артаньян йөзекне кире кайтарып бирмәкче булды, ләкин миледи аны алмады.

— Юк, юк, мине сөюегезнең бер билгесе булып сездә калсын ул...— диде. Дулкынланган бер тавыш белән: — Аннан ары, бу йөзекне алып, сез, үзегез дә белеп бетермәстән, миңа зур ярдәм күрсәтәсез,— дип куйды.

Д'Артаньян күңеленнән: «Бу хатынның эче тулы сер икән»,— дип уйлады.

Бу минутта ул миледига хәлнең чын-дөресен сөйләп бирәсе килүен тойды, үзенең кем булуын һәм бирегә үч алу нияте белән килгәнлеген әйтим дип авызын ачуга, миледи әйтә куйды:

— И бичара дустым, теге явыз, Гасконь егете дим, сезне үтерә язган бит.

Явыз дигәне д'Артаньян инде.

— Яраларыгыз әле һаман сызлыймы? — дип сорады миледи.

— Әйе, бик сызлый шул,— диде д'Артаньян, ни дип әйтергә белмичә.

— Борчылмагыз, сезнең өчен мин аннан үч алырмын, минем үчем аяусыз булыр! — дип пышылдады миледи.

«Юк! Безнең арада дөресен әйтеп сөйләшер вакыт житмәгән әле»,— дип уйланды д'Артаньян.

Шушы кыска диалогтан соң д'Артаньян беркадәр исенә килә алмыйчарак торды, миледидан үч алу нияте әллә кая юкка чыкты. Бу хатынның үз иркенә буйсындыра торган шаккаткыч бер кодрәтле көче бар иде, егет аны күңеленнән дошман күрә һәм шул ук вакытта гүзәл бер зат итеп тә күрә: моңарчы ул бер күңелдә шундый капма-каршы ике тойгы туа алыр да, икесе бергә кушылып, әллә ниткән гаҗәеп-сәер бер мәхәббәткә әйләнер дип һич ышанмый иде.

Ул арада инде сәгать берне сукты, аерылышыр вакыт житте. Миледи яныннан чыгып киткән чагында д'Артаньянның

күңелендә «Их, каласы иде бит!» дигән үкенечле бер тойгыдан башка кичерешләр булмады, кайнар дәрт белән үбешкән вакытларында киләсе атнада тагын очрашырга дип вәгъдәләштеләр. Бичара Кәтти д'Артаньян аның бүлмәсе аша узган чакта егет белән аз гына булса да сөйләшеп кала алырмын дип өметләнеп көтеп тора иде, ләкин миледи караңгыда егетне үзе озата чыкты һәм аның белән баскычта гына саубуллашты.

Иртәгесе көнне иртән д'Артаньян Атос янына йөгерде. Мондый гаҗәп бер хәлгә эләккәч, егеткә өлкән дустыннан киңәш ишетү кирәк иде. Д'Артаньян аңа бөтен хәлне сөйләп бирде; ул сөйләгән чакта Атос берничә тапкыр кашын җыергалады.

— Сезнен миледиегыз җирәнгеч бер зат булып тоела, шулай да сез, аны алдап, хата кылгансыз: тегеләй дә, болай да сез үзегез өчен коточкыч бер дошман тудыргансыз,— диде ул.

Шушы сүзен әйткән чагында Атос дикъкать белән д'Артаньянның бармагындагы алмаз кысалы зәңгәр якутка күз төшерде — королева бүләк иткән йөзеген исә д'Артаньян тартмага салып җыеп куйган иде.

Гасконь егете, шундый кыйммәтле бүләге белән дуслары алдында мактана алуына горурланып:

— Бу йөзеккә күзегез төштеме әллә? — дип сорады.

— Әйе, бер гаиләнең мирас итеп саклаган йөзеген хәтерләтә ул,— диде Атос.

— Бик матур йөзек, әйе бит? — дип куйды д'Артаньян.

— Бик шәп йөзек шул! — диде Атос та.— Дөньяда берберенә ике тамчы су кебек охшаган ике зәңгәр якут булыр дип һич уйламаган идем. Сез аны үзегезнең алмазыгызга алыштырып алдыгызмы әллә?

— Юк, гүзәл инглиз ханымның, дөресрәге француз ханымның миңа бүләге бу, чөнки үзеннән сорашмасам да, аның Франциядә туганлыгына минем иманым камил.

— Сез бу йөзекне миледидан алдыгызмыни? — дип кычкыра төшебрәк сорады Атос, тавышыннан бик нык дулкынлануы сизелде.

— Әйе, моны ул миңа бүген төнлә бүләк итте.

— Кая, күрсәтегез әле шул йөзекне,— диде Атос.

— Менә,— дип, д'Артаньян йөзекне бармагыннан салды.

Атос йөзекне җентекләбрәк карады да агарынып китте, шуннан соң аны сул кулының атсыз бармагына киеп карады; йөзек, шул бармакка үлчәп ясалган кебек, таман гына иде. Атосның гадәттәге тыныч-сабыр йөзе ачу һәм гарьлектән каралып-усалланып китте.

— Моның шул ук йөзек булуы мөмкин түгел,— диде ул,— леди Кларик кулына ничек барып эләксен икән ул? Шул ук вакытта ике йөзек арасында бу кадәр охшашлык булуына да ышануы кыен.

— Бу йөзек сезгә танышмыни? — дип сорады д'Артаньян.

— Таныш йөзек кебек тоелган иде дә, ялгышканмын, күрәсең,— диде Атос.

Шулай дигәч, йөзектән күзен алмастан, аны д'Артаньянга кайтарып бирде.

— Менә нәрсә, д'Артаньян,— диде ул бераздан,— бу йөзекне бармагыгыздан салыгыз сез, я ташын эчкә каратып киегез. Бу йөзек минем өчен бик авыр хатирәләрне искә төшерә, юкса мин сезнең белән тыныч кына сөйләшә алмам. Сез минем белән ни турындадыр киңәшмәкче идегез бугай, нишләргә икән, дигән идегез... Туктагыз әле... шул зәңгәр якутны тагын бер тапкыр күрсәтегез әле. Мин әйткәненең бер кырында тырналган җире булырга тиеш; бер хәл аркасында шулай булган иде.

Д'Артаньян йөзекне, янә бармагыннан салып, Атоска бирде.

Атос сискәнеп куйды.

— Менә карагыз, гаҗәп түгелме инде бу? — диде һәм д'Артаньянга ташның тырналган төшен күрсәтте.

— Бу зәңгәр якут сезгә кемнән калган иде соң, Атос?

— Әниемнән калган иде, әнигә әнисеннән калган булган. Әйткәнемчә, бик күптәннән килә торган гаилә мирасы ул... безнең гаиләдән беркайчан да читкә чыгарга тиеш түгел иде.

— Сез аны... саткан идегезме әллә? — дип кыяр-кыймас кына сорады д'Артаньян.

Атос, сәер генә елмаеп:

— Юк,— диде.— Менә бүген сезгә бүләк иткән кебек, мин дә аны төнлә сөйгәнемә бүләк иткән идем.

Д'Артаньян уйга калды; милединың күңеле караңгы, төпсез бер упкын булып күз алдына килде аның.

Шуннан соң йөзекне бармагына кимәде, кесәсенә генә салып куйды.

— Карагыз әле,— диде Атос, дустының кулыннан тотып,— д'Артаньян, минем сезне яратканымны беләсез. Үз улымны да мин сезне яраткан кебек ярата алмас идем. Ышаныгыз сүземә, ташлагыз сез ул хатынны. Мин аны белүен белмим, шулай да күңелем сизә: мордар киткән бер заттыр ул, куркыныч, шомлы зат.

— Хак сөйлисез. Мин аны ташлыйм. Дөресен әйтим: ул хатыннан мин үзем дә куркам,— диде д'Артаньян.

— Ташларга көчегез җитәрме соң? — дип сорады Атос.

— Җитәр. Мин ул эшне озакка сузмам,— диде д'Артаньян.

— Яхшы, энем. Алай итеп бик дөрес эшлисез,— диде Атос, аталарча бер ярату белән Гасконь егетенең кулын кысты.— Тормышыгызга яңа килеп кенә кергән ул хатын, ходай кушып, яман эзен генә калдыра күрмәсен.

Шуннан соң Атос, ялгызым гына калып уйлыйсы уйларым бар дигәнне аңлатып, д'Артаньянга баш изәде.

Д'Артаньян өенә кайтып керсә, анда аны Кэтти көтеп утыра иде. Бичара кыз әлеге йокысыз, газаплы төннән соң бөтен-

ләй чырайсыз калган, ай буе каты авырып ятса да бу кадәр бетерешмәстер кебек иде.

Байбикәсе аңа де Вард янына барып кайтырга кушкан икән. Миледи мәхәббәте шаукымыннан шаша язган, шул бәхетеннән тәмам исергән икән. Сөйгән егетенең тагын кайчан кавышырга теләвен беләсе килә икән.

Бичара Кэтти, йөзеннән каны качкан бер хәлдә, калтыранакалтырана, д'Артаньянның җавабын көтте.

Атосның егеткә йогынтысы зур иде. Менә хәзер миледидан үч алып, ачу-гарьлеге басылганнан соң, дустының акыл-киңәше, үзенең йөрәк авазына кушылып, егеткә миледи белән араны өзәрлек көч бирде. Җавап урынына ул кулына каләм алды да болай дип язды:

«Ханым, якындагы берничә көндә минем белән күрешергә өметләнмәгез, савыгып җиткәннән бирле андый эшләрем күбәеп киткәнлектән, аларны беркадәр тәртипкә китерергә туры килде. Чиратыгыз җиткәч, сезгә ул хакта хәбәр итәрмен.

Кулларыгызны үбеп,<br>*граф де Вард*».

Зәңгәр якут хакында бер сүз дә әйтелмәде: Гасконь егете әллә моны миледига каршы бер корал итеп сакларга уйлады микән? Әллә — яшерен-батырын түгел — бу зәңгәр якутны, бүтән чарасы булмаса, гаскәри кирәк-ярак юнәтергә ярап куяр дип үзендә калдырдымы?

Хәер, бер заманда кылган гамәлләрне икенче заман карашыннан чыгып юрау дөрес тә булмас иде. Безнең чорда һәрбер җүнле кеше үзе өчен хурлык дип санардай нәрсә ул заманда бик гади, табигый бер нәрсә булып тоелган һәм иң яхшы гаиләдә үскән егетләр дә гадәттә сөяркәләре исәбенә яшәгәннәр.

Д'Артаньян хатны Кэттига ябыштырмыйча гына бирде; кыз аны укып карагач башта төшенмичәрәк торды, аннары, тагын бер тапкыр укыгач, шатлыгыннан нишләргә белмәде.

Мондый бәхеткә ышанмады ул; д'Артаньян кызны хатта язылганнарга телдән әйтеп ышандырырга мәҗбүр булды, һәм, әлеге хатны тапшырган чакта бичара кызга холыксыз миледидан кыен эләгү куркынычы булса да, Кэтти йөгерә-йөгерә Король мәйданына кайтып китте.

Хатын-кызның иң яхшысы да көндәшен кызганмый шул.

Кэтти хатны ашыгып алып кайткан кебек, миледи да аны ашыга-кабалана ачты. Тик хатны укый башлау белән үк хатынның чырае агарынып китте, аннары ул кәгазьне йомарлады да Кэттига таба борылды, күзләре очкынланып ялтырап китте.

— Нинди хат бу? — дип сорады.

— Җавап хаты, ханым,— диде Кэтти, калтырана-калтырана.

— Булмас! — дип кычкырып җибәрде миледи.— Булмас, дворян кеше хатын-кызга мондый хат язмас.

Шулай диде дә кинәт сискәнеп-тетрәнеп китте.

— Ай аллам! — дип пышылдады.— Белде микәнни?..— дип тукталып калды.

Миледи тешен шыкырдатты, чыраена көл төсе иңде. Тәрәзә янына барып, саф һава суламакчы булып талпынган иде дә, шунда таба кулын гына суза алды, аннары аяклары сыгылып китеп, креслога ауды.

Кэтти, аны һушыннан язды дип белеп, янына йөгереп килде, изүен ычкындырмакчы булды, әмма миледи шундук торып басты...

— Ни кирәк сезгә? Орынасы булмагыз миңа! — дип кычкырды.

Милединың мондый куркыныч кыяфәтен күреп коты алынган асрау кыз:

— Ханым, мин сезне һуштан яздыгыз дип белдем, ярдәм итмәкче идем,— дип сөйләнде.

— Хуштан язган?! Мин?! Мин?! Нечкә күңелле бер җилбәзәк хатын дип белдегезме әллә мине?! Үземне мәсхәрә иткән чакта һушымнан язмыйм мин, шуның өчен үч алам мин — ишеттегезме?

Шулай диде дә Кэттига чыгып китәргә ымлады.

## *VI*

## *ҮЧ АЛУ ХЫЯЛЫ*

Кичен миледи д'Артаньянны килү белән үк үзе янына кертергә кушты. Ләкин егет килмәде.

Икенче көнне иртән Кэтти, д'Артаньян янына килеп, кичәге хәлләрнең бөтенесен егеткә сөйләп бирде. Егет елмаеп куйды; аның үч алуының максаты да милединың әнә шул көнчелек зәһәрен кузгату иде.

Бу көнне кич милединың кәефе узган көндәгедән дә начаррак иде, һәм ул тагын, Гасконь егете килсә, үзе янына кертергә кушты, әмма бу юлы да милединың көтүе бушка гына булды.

Иртәгесе көнне Кэтти д'Артаньян янына килде, ләкин асрау кыз узган ике көндәге кебек шат чырайлы, терчә-уяу түгел, киресенчә, кыяфәте бик моңсу-ямансу иде. Д'Артаньян бичара кыздан: «Ни булды?» — дип сорады. Кыз җавап урынына кесәсеннән егеткә хат чыгарып бирде.

Хат миледи кулы белән язылган, тик бу юлы граф де Вардка түгел, бәлки д'Артаньянның үз исеменә атап җибәрелгән иде.

Егет хатны ачып укырга кереште:

«Хөрмәтле д'Артаньян әфәнде, дусларыгызны онытып бетерү яхшы түгел, озак вакытка аерылышасы булганда — бигрәк тә. Кичә һәм өченче көн лорд Винтер белән мин сезне бик көткән идек — килмәдегез. Бүген дә шул хәл кабатланыр микән?

Сезгә чын рәхмәтләремне белдереп,

*леди Кларик».*

— Бик аңлашыла, мондый хатның булырын көткән идем. Граф де Вардка өмете кимегән саен минем өмет арта гына бара,— диде д'Артаньян.

— Алайса киләсез? — дип сорады Кэтти.

— Карале, кадерлем,— диде Гасконь егете, Атоска биргән вәгъдәсен бозарга ниятләвен үз күз алдында акларга тырышып,— аңла син шуны: шулкадәр тәгаен әйтеп чакырган чагында бармый калу бер дә акыллы эш булмас иде бит. Әгәр мин бармасам, минем ни сәбәпле анда барып йөрүдән туктавым миледига аңлашылып бетмәс иде, шуннан соң аның кайбер нәрсәләрне сизенүе дә ихтимал. Андый хатынның холкын кем белеп бетергән: әллә ниләр эшләтеп үч алуы мөмкин.

— И аллам! — дип көрсенеп куйды Кэтти,— сез шундый итеп сөйлисез — үзегез гел дөрес, гел хаклы булып чыгасыз. Сез, мөгаен, тагын аның күңелен күреп йөри башларсыз, әгәр инде бу юлы сез аңа чын үз исемегез белән ошап китсәгез, әгәр аңа чын йөзегез ошаса, баштагыдан күп өлеш яманрак булачак бит!

Бичара кыз алда буласы хәлләрнең беркадәрен күңеле белән сизеп-белеп үк тора иде инде.

Д'Артаньян булдыра алганча аны тынычландырырга-юатырга тырышты, милединың ягымына алданмам дип сүз бирде.

Леди Кларикка исә ул: мәрхәмәтегез өчен бик зур рәхмәтемне белдерәм һәм үземне сезнең карамакка тапшырам, дип әйтергә кушты кызга. Язуымны милединың үткен күзе сизмәслек дәрәҗәдә үзгәртә алмам дип, хат-мазар язарга батырчылык итмәде.

Нәкъ сәгать тугызда д'Артаньян Король мәйданында иде инде. Алгы бүлмәдәге хезмәтчеләр алдан ук кисәтеп куелган булган, күрәсең,— д'Артаньян йортка килеп керүгә, мушкетер егет милединың кабул итү-итмәвен сорарга өлгергәнче үк, бер хезмәтче аның килүе хакында миледига әйтергә йөгерде.

— Рәхим итсен,— диде миледи, кыска гына итеп, әмма тавышы шундый каты яңгырады — д'Артаньян моны алгы бүлмәдән үк ишетте.

Лакей аны кунак бүлмәсенә озатып куйды.

— Кем килсә дә, мин өйдә юк. Ишеттегезме? Кем килсә дә,— диде миледи.

Лакей чыгып китте.

Д'Артаньян кызыксынып миледига күз салды: ханымның йөзе агарыбрак киткән, күзләре,— әллә елаганнан, әллә төннә-

рен юньләп йокламаганнан,— бик талчыккан сыман күренә иде. Бүлмә эче гадәттәге кебек үк якты түгел, шулай да, аны махсус ярым караңгы итүгә карамастан, яшь ханым соңгы ике көндәге каты кичерешләренең эзләрен яшереп бетерә алмаган иде.

Д'Артаньян гадәттәгечә мөлаем бер төс белән ханымга якынрак килде. Миледи, үзен көчләп-мәҗбүр итеп, ачык чырай белән елмайган булды, ләкин аның бу елмаюы дулкынланудан бозылган чыраена бигүк ярашып-килешеп бетми дә иде.

Д'Артаньян ханымның кәефен сорады.

— Кәефем начар, бик начар,— диде миледи.

— Ул чагында мин сезгә комачаулаганмындыр. Сезгә, әлбәттә, ял итәргә кирәк, алайса мин хәзер үк кайтып китәм,— диде д'Артаньян.

— Юк, юк! Киресенчә, китмәгез, д'Артаньян әфәнде, сезнең белән сөйләшеп утырсам, кәефем яхшыра гына төшәр,— диде миледи.

«Оһо! Моның бу кадәр мәрхәмәтле булганы юк иде әле, уяу булырга кирәк»,— дип уйланды д'Артаньян.

Миледи булдыра алган кадәр дустанә тонга күчте һәм әңгәмәне бик җанландырып җибәрергә тырышты. Бик азга гына басылып торган ярсулы кичерешүе яңадан башланды, күзләре тагын ялтырап-ялтырап китте, яңаклары кызарып чыкты, иреннәре алсуланып китте. Д'Артаньян каршында янә үзенең гүзәллеге белән егетне әсир иткән Цирцея утыра иде. Егетнең сүнгән-беткән дип санаган мәхәббәт тойгылары басылып кына торган һәм хәзер яңадан баш калкыта башлаган иде. Миледи искиткеч матур итеп елмая һәм д'Артаньян аның шушы елмаюы өчен җанын бирергә дә әзер кебек иде.

Бер ара ул үкенү сыман бер тойгы да кичереп алды.

Милединың исә торган саен теле ачыла-чишелә барды. Ул д'Артаньяннан: «Сөяркәгез бармы?» — дип сорады.

— Аһ! — дип куйды егет, иң ягымлы бер тавыш белән.— Сез миңа шундый сораулар биреп шулкадәрле мәрхәмәтсез дә була беләсезмени? Мин бит сезне күргәннән бирле фәкать сезне генә уйлап, сезнең өчен генә ут йотып яшим!

Миледи сәер генә елмаеп куйды.

— Сез мине яратасызмыни? — дип сорады.

— Ул хакта әйтеп торыйммыни, үзегез шуны сизмәдегезмени?

— Ярый, сиздем дә ди, әмма үзегез дә беләсездер: йөрәктә горурлык хисе никадәр күбрәк булса, аны әсир итүе дә шулкадәр авыррак була бит.

— О, мин кыенлыклардан курыкмыйм, бары тик мөмкин булмастае гына куркыта мине,— диде д'Артаньян.

— Чын мәхәббәт өчен мөмкин булмастай бернәрсә дә юк ул,— диде миледи бу сүзгә каршы.

— Бернәрсә дәме, ханым?

— Бернәрсә дә,— дип кабатлады миледи.

«Шайтан алгыры! — диде д'Артаньян көнеленнән.— Тавышы-тоны бөтенләй үзгәрде бит. Бу көйсез хатын әллә миңа гашыйк булдымы, әллә миңа да, де Вардка дип бүләк иткән шикелле, икенче зәңгәр якутын бүләк итәргә җыенамы?»

Д'Артаньян үзенең урындыгын тиз генә милединың креслосына табарак шудырды.

— Әйтегез әле, яратам дигәнегезне сез ни белән исбат итәр идегез соң? — дип сорады хатын.

— Сез ни телисез — шуның белән. Боерыгыз гына — баш өсте.

— Бөтенесен дәме?

— Бөтенесен дә! — дип кычкырып җавап кайтарды д'Артаньян — болай бик олыдан кубып сүз бирсә дә, әллә ни күп югалтмаячагын ул алдан ук белеп тора иде.

— Яхшы! Ул чагында сөйләшеп карыйк,— диде миледи, үз нәүбәтендә ул да креслосын д'Артаньянның урындыгына табарак күчерде.

— Мин сезне тыңлыйм, ханым,— диде егет.

Миледи, уйга калган һәм икеләнгәнрәк кебек, беравык дәшми торды; шуннан соң сөйләшергә карар итте, күрәсең.

— Минем бер дошманым бар,— диде.

— Сезнең, ханым? — диде д'Артаньян бик гаҗәпләнгән булып.— И аллам! Андый хәлнең дә булуы мөмкинмени? Сез бит шундый гүзәлсез, шундый мәрхәмәтлесез!

— Кан дошманым.

— Чыннан дамы?

— Ул дошманым мине бик яман мәсхәрә итте — безнең арада хәзер үлем сугышы гына. Мин сезнең ярдәмчем булырыгызга өметләнә аламмы?

Д'Артаньян бу үчлекле затның үзеннән ни теләгәнен шундук төшенде.

— Өметләнә аласыз, ханым,— диде ул, кәпрәя төшеп,— мәхәббәтем белән бергә, минем кылычыма да, җаныма да сез хуҗа.

— Ул чагында, әгәр сез гашыйк булган дәрәҗәдә үк олы җанлы да икәнсез...— Миледи шулай диде дә тынлып калды.

— Ул чагында нәрсә? — дип сорады д'Артаньян.

— Ул чагында,— диде миледи беравык тынып торганнан соң,— ул чагында сез бүгенге көннән башлап мөмкин булмастай нәрсәләрдән курыкмаска тиешсез.

Д'Артаньян, кычкыра төшеп:

— Юк, мин мондый бәхеткә түзә алмыйм! — диде дә, милединың каршына тезләнеп, аның кулларын кайнарланып үбәргә кереште — ханым кулын тартып алмады.

«Шул кабахәт де Вардтан минем өчен үч ал, аннары инде син ахмактан, синең ише сукыр коралдан котыла белермен мин...» — дип уйланды миледи, тешен кысып.

«Үз иркең белән килеп кер син минем кочагыма, икейөзле хәтәр хатын, килеп кер кочагыма! Шуннан соң мин, миннән үтертергә теләгән кешең белән бергәләп, элекке мыскыл итүләрең өчен рәхәтләнеп бер көләрмен»,— дип уйланды д'Артаньян.

Егет башын күтәрде дә:

— Мин әзермен,— диде.

— Димәк, сез мине аңладыгыз, сөекле д'Артаньян? — диде миледи.

— Мин сезнең ни теләгәнегезне карашыгыздан ук сиздем.

— Алайса, сез минем хакка атаклы кылычыгызны кынысыннан суырып чыгарырга риза?

— Кайчан теләсәгез дә.

— Ә моның әҗерен ни белән кайтарып түләрмен икән соң мин? — диде миледи.— Гашыйкларны беләм мин: алар бернәрсәне дә бушка эшләмиләр.

— Сез минем нинди бүләк турында хыялланганымны беләсез — сезгә дә, миңа да лаек булган бердәнбер бүләк ул! — дип җавап кайтарды д'Артаньян.

Шулай дигәч, ул аны бик яратып үзенә таба тартты.

Миледи каршылык күрсәтмәде диярлек.

— Комсыз! — диде ханым, елмаеп.

— Аh! — дип кайнар бер хискә бирелеп әйтеп куйды д'Артаньян — бу хатынның, чыннан да, егетнең йөрәгендә шундый кайнар хис уятырлык сәләте бар иде шул.— Минем бу бәхетемә акылым ышанмый, мин аны хыял кебек очып китеп юкка чыгар дип гел куркып яшим, шуңа күрә мин аны чынга ашырырга ашыгам.

— Алайса, хыялыгыздагы ул бәхеткә казганып ирешегез соң.

— Мин сезнең карамагыгызда,— диде д'Артаньян.

Миледи, соңгы тамчы шиген дә күңеленнән куып:

— Чынлапмы? — дип сорады.

— Шушы гүзәл күзләрне елатырга батырчылык иткән ул түбән җанлы бәндәнең исемен әйтегез миңа.

— Ә мине елаган дип кем әйтте әле сезгә?

— Миңа шулай тоелган иде...

— Минем ише хатыннар еламыйлар,— диде миледи.

— Алай булгач, бик яхшы! Ягез, ул бәндәнең исемен әйтегез инде.

— Уйлап карагыз: аның исемен әйтү үземнең бөтен серемне ачып салу дигән сүз бит ул.

— Ләкин мин ул исемне белергә тиеш бит.

— Әйе, белергә тиешсез. Менә, күрәсезме, ничек ышанам мин сезгә!

— Мин бик бәхетлемен. Ул бәндәнең исеме?

— Ул кешене сез беләсез.

— Беләм?

— Әйе.

Д'Артаньян, миледи каршында берни белмәгән булып күренү өчен:

— Минем дусларымнан берәрсе түгелдер бит? — дип сорады.

— Алайса, ул кеше сезнең дусларыгыздан берәрсе булса, сез икеләнер идегезме? — дип кычкырып сорады миледи һәм күзләрендә дәһшәтле бер чаткы ялтырап китте.

Д'Артаньян хискә бирелгән кебек кычкырып җавап кайтарды:

— Юк, бертуган абыем булса да икеләнмәс идем!

Безнең Гасконь егете үзе өчен бернинди хәтәрлеккә бармый, нык ышанып эш итә иде.

— Сезнең мондый тугрылыгыгыз ошый миңа,— диде миледи.

— Һай, минем шул гына ягым ошыймыни сезгә? — дип сорады д'Артаньян.

— Түгел, мин сезне дә, сезнең үзегезне дә яратам,— диде ханым, егетнең кулыннан тотып.

Д'Артаньян, кулының кайнар бер кысу белән кысылуын тоеп, бөтенләй калтырана ук башлады. Гүяки миледи кичергән ярсулы тетрәнү аның тәненә дә күчте.

— Сез мине яратасыз! О, акылларымнан язам бугай мин! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды егет һәм ханымны кочып та алды.

Миледи аның үбүенә каршы килмәде, шулай ук каршы җавап та бирмәде.

Аның иреннәре салкын иде: д'Артаньян таш статуя үпкән кебек хис итте үзен.

Шулай да егетнең сөенече һушларына киткән, йөрәгендә мәхәббәт ялкыны дөрләп яна иде; ул үзен миледи ярата икәнлегенә ышана язды, хәтта де Вардның җинаять кылган булуына да ышана язды. Әгәр де Вард хәзер менә шушында, аның янында булса, ул аны үтергән дә булыр иде.

Миледи шушы минуттан файдаланып калырга тырышты.

— Аның исеме...— дип сүзгә керешкән иде, д'Артаньян:

— Де Вард, беләм мин! — дип әйтеп ташлады.

Миледи шундук аны кулларыннан тотып алды да егетнең күңел түренә күз салырга тырышкандай текәлеп:

— Каян белдегез сез аны? — дип сорады.

Д'Артаньян, мавыгып китеп, хаталык эшләгәнлеген төшенде.

— Әйтегез, әйтегез, әйтегез инде! Каян белдегез сез аны? — диде миледи.

— Мин каян белдемме? — дип кайтарып сорады д'Артаньян.

— Әйе, каян?

— Кичә мин бер йортта де Вард белән очрашкан идем, шунда ул миңа йөзек күрсәтте, йөзекне сез бүләк иткән булуыгызны әйтте.

— Кабахәт! — дип кычкырып әйтеп куйды миледи.

Бу сүз, билгеле сәбәпләр аркасында, д'Артаньянның йөрәгендә яңгырап кабатланды.

— Я, шуннан? — диде миледи, төпченгән бер төс белән.

— Шуннан шул — мин ул кабахәт адәмнән сезнең үчегезне кайтарачакмын,— диде д'Артаньян, гайрәтле бер төс белән.

— Рәхмәт, батыр дустым! — диде миледи, кычкыра төшебрәк.— Минем үчемне кайчан кайтарачаксыз инде?

— Иртәгә ук, шушы минутта ук, кайчан телисез.

Миледи да «шушы минутта ук» дип кычкырып җибәрә язды, ләкин болай бик ашыгу д'Артаньянга карата беркадәр ихтирамсызлык күрсәтү булыр дип тыелып калды.

Өстәвенә, аның әле бу эшнең теге ягын, бу ягын уйлыйсы һәм үзен яклаучы егеткә секундантлар алдында граф белән аңлашуны булдырмау хакында бик күп акыл-киңәшләр бирәсе бар иде. Д'Артаньянның бер җөмләсе аркасында милединың бөтен шик-шөбһәсе юкка чыкты.

— Иртәгә мин я сезнең өчен үч кайтарам, я үлеп калам,— диде егет.

— Юк! Сез минем өчен үч алырсыз, ләкин үлмәссез. Куркак җан ул,— диде миледи.

— Хатын-кыз янында куркактыр, бәлки, ә ирләр каршында андый түгел. Кем-кем дигәндә дә, аны бераз беләм инде мин.

— Ялгышмасам, аның белән сугышканда сезгә язмыштан зарланырга туры килмәгән иде шикелле.

— Язмыш ул — җилбәзәк хатын кебек, бүген алдын күрсәтсә, иртәгә артын күрсәтүе дә ихтимал.

— Ягъни, сез икеләнә башладыгыз?

— Юк, алла сакласын, икеләнмим, ләкин мине коры өмет белән генә юатып, үлемгә җибәрү гадел эш булыр микән соң?

Миледи: «Аһ, эш шуңа гына терәлеп калса, кыюрак булыгыз соң!» дигән сыман бер караш белән җавап кайтарды. Һәм шул күз карашын аңлатып, ягымлы гына итеп:

— Сүзегез хак,— диде.

— О, фәрештә сез! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян.

— Димәк, без барысын да сөйләштек-килештек? — дип сорады миледи.

— Мин сездән үтенгәннән башкалары хакында, кадерлем.

— Әгәр мин, минем яратуыма ышана аласыз, дисәм?

— Минем иртәгәге көнем юк, мин көтә алмыйм.

— Акрынрак! Абыемның аяк тавышын ишетәм. Ул сезне монда күрергә тиеш түгел.

Миледи кыңгырау чыңлатты. Бүлмәгә Кэтти килеп керде.

Ханым, кечкенә генә бер яшерен ишекне ачып:

— Менә шушы ишектән чыгыгыз, сәгать унбердә килерсез. Әңгәмәбезне шунда сөйләшеп бетерербез. Кэтти сезне минем янга озатып куяр,— диде.

Миледи шушы сүзләрен әйткән чакта бичара кыз чак кына һушыннан язмый калды.

— Я, туташ! Нигә таш сын кебек катып калдыгыз? Мин әйткәнне ишеттегезме? Бүген кич сәгать унбердә д'Артаньян әфәндене минем янга озатып куярсыз.

«Бөтен күрешү-кавышуларын сәгать унбергә сөйләшә икән бу. Гадәтенә әйләнгәндер»,— дип уйланды д'Артаньян.

Миледи кулын сузуга, егет бик мөлаем бер төс белән аның кулын үпте.

Киткән чакта исә, Кэттиның шелтәләренә аннан-моннан гына җавап кайтаргалап: «Әмма мин үзем ахмак булып калмагаем! Һичшиксез, бу хатын теләсә нинди җинаять эшләргә дә сәләтле бит, сак булырга кирәк»,— дип уйланды.

## VII

## МИЛЕДИНЫҢ СЕРЕ

Д'Артаньян, Кэттиның гозерләп үтенүенә дә карамастан, йорттан чыккач, кыз янына менмәде; болай итүенең ике сәбәбе бар иде: беренчедән, кызның үпкә-сапка, шелтәләрен, үтенечләрен ишетәсе килми, икенчедән, аның ялгызы гына калып, уйларының рәтенә чыгасы бар һәм шулай ук, булдыра алган кадәр, әлеге хатынның да уй-ниятләрен төшенәсе бар иде.

Бу маҗараларда бердәнбер аңлаешлы нәрсә шул — д'Артаньян миледины шашып яратса, хатын аны бөтенләй яратмый иде. Д'Артаньянның күңеленә мондый бер уй да килде: аның өчен иң яхшысы — өйгә кире барып, миледига тәфсилләбрәк хат язу һәм моңарчы де Вард та, ул да бер үк кеше икәнлеген, шулай булгач, де Вардны үтерү үз-үзеңне үтерү икәнлеген яшермичә әйтү булмас микән? Әмма, алай эшләсә, аның үзен дә бик яман үч көтәчәк бит; егетнең әлеге хатынны тагын бер тапкыр, бу юлы инде чын үзе булып кочагына аласы килә, бу үчнен аның өчен билгеле бер рәхәт ләззәте дә булганлыктан, егет хатыннан ваз кичә дә алмый иде.

Ул, ун адым саен кире кайтып, миледи бүлмәләреннән тәрәзә капкачлары аша саркып торган утны карый-карый, Король мәйданын биш-алты тапкыр әйләнеп чыкты; бүген миледи, беренче мәртәбәсендәге кебек, йокы бүлмәсенә кереп китәргә ашыкмый, монысы тәгаен иде.

Ниһаять, ут сүнде.

Шушы ут белән бергә д'Артаньян күңелендәге икеләнүнең соңгы эзләре дә юкка чыкты; ул беренче төндәге хәлләрне исе-

нә төшерде һәм, йөрәге сулкылдый-сулкылдый, битләре ут кебек янган хәлдә, йортка барып керде дә Кэтти бүлмәсенә ташланды.

Чырае көл төсле агарынган, бөтен тәне дер-дер калтыранган Кэтти сөйгән егетен тегендә кертмәскә тырышып карады, әмма миледи тавышларга колак салып торган, күрәсең,— д'Артаньянның килгәнен ишетеп, ишекне ачты да:

— Керегез,— диде.

Бу эш шулкадәр дә шаккаткыч оятсызлык, коточкыч бер әрсезлек белән эшләнде ки, д'Артаньян күргән-ишеткәнен беравык акылына сыйдыра алмый торды. Ул үзен төштә генә була торган фантастик бер маҗараның каһарманы итеп хис кылды.

Шуңа да карамастан, егет, тимер магнитка тартылган кебек, үзен тарткан көчкә бирешеп, миледига таба омтылды.

Алар кереп китүгә ишек ябылды.

Кэтти шул ишеккә таба ташланды.

Гашыйк кызның йөрәгендә кайнаган барлык тойгылары — көнләшү, ярсу, гарьлек хисләре — хәлне фаш итәргә өнди, ләкин кыз үзенең шул интригага катнашуын туп-туры әйтеп бирсә, харап кына булыр, өстәвенә, д'Артаньянны да бөтенләй югалтыр иде. Мәхәббәте тудырган бу соңгы уй шушы соңгы корбанны бирергә мәҗбүр итте.

Д'Артаньянга килгәндә исә, ул барлык теләгенә иреште: хәзер инде миледи аны икенче бер кеше итеп түгел; бәлки үзе итеп ярата яки яраткан булып күренергә тырыша иде. Дөрес, эчке, яшерен бер аваз егеткә үзенең фәкать үч алу коралы гына булуын, аны кеше үтерсен өчен генә иркәләгәнлекләрен әйтеп тора, әмма егетлек горурлыгы, мин-минлеге, шашкын хисләре бу авазны, бу өнне басып-томалап китә. Өстәвенә, белгәнебезчә, үз-үзенә ышанычы шактый зур булган Гасконь егете, күңеленнән үзен де Вард белән чагыштырып: «Ә нигә әле мине үзем булганым өчен сөймәскә?» — дип тә куя иде.

Шулай итеп, д'Артаньян бөтенләе белән шушы минуттагы тойгы-кичерешләр иркенә бирелде. Хәзер инде миледи аңа бер мизгелгә генә йөрәгенә курку салган әлеге шомлы бер хатын булып тоелмады; хәзер инде ул бөтенләе белән мәхәббәт ялкынына бирелгән дәртле сөяркә иде, бу ялкынны егет үзе дә кичерә кебек иде. Шул хәлдә ике сәгатьләп вакыт узды.

Ул арада инде гашыйкларның ялкынлы дәртләре сүрелә төште. Д'Артаньян кебек бөтенләй онытылып китәрлек сәбәбе булмаган миледи беренче булып күңел исереклегеннән айныды да егеттән: «Иртәгә граф де Вардны дуэльгә чакыру өчен берәр сылтау уйлап тапмадыгызмы?» — дип сорады.

Мәгәр д'Артаньянның уйлары хәзер бөтенләй башка тирәдә йөри, ул дөньяда гаме булмаган бер кеше кебек бөтенесен дә оныткан иде, шуңа күрә егет: «Дуэль турында уйларга хәзер вакыт соң инде»,— дип шаяртып кына җавап кайтарды.

Миледи, бөтен күңелен биләгән бу нәрсәгә карата мондый

гамьсезлек күрсәтелүен ишеткәч, шикләнә-курка калды, берсеннән-берсе таләпчәнрәк сораулар бирә башлады.

Тузга язмаган бу дуэльне чынлап торып уена да алмаган д'Артаньян исә шуннан соң сүзне икенчегә бормакчы булып карады, ләкин бу эш аның хәленнән килерлек түгел иде инде.

Милединың катгый акылы һәм корычтай ихтыяры д'Артаньянга хатын үзе алдан билгеләп куйган чиктән чыгып китәргә юл куймады.

Д'Артаньян миледига: «Де Вардны кичерегез, андый яман ниятләрегезне ташлагыз», диюдән дә тапкыррак башка киңәш әйтә алмады.

Егеттән мондый сүзләр ишетә башлауга ук яшь ханым дерт итеп сискәнеп китте дә егеттән читләшә төште. Карангыда әллә ничек сәер яңгыраган әче бер тавыш белән:

— Әллә инде курка да башладыгызмы, сөекле д'Артаньян? — дип көлеп әйтеп куйды.

— Ничек шулай уйлый аласыз сез, кадерлем! — диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.— Әгәр дә ул бичара граф де Вардның гаебе сез уйлаганнан күп өлеш азрак булса?

— Азракмы, күбрәкме,— барыбер мине алдады ул, шулай булгач, ул үләргә тиеш,— диде миледи, усал-кырыс бер тавыш белән.

— Ярар, сез аңа хөкем чыгаргансыз икән — үлә бирсен,— диде д'Артаньян, нык бер тавыш белән. Аның бу тавышыннан миледига егетнең чиксез тугрылыгы сизелгән кебек булды һәм ул яңадан д'Артаньянга елыша төште.

Миледи өчен бу төн артык озын булып тоелгандырмы-юкмы — анысын без әйтә алмыйбыз, ә менә д'Артаньянга ул әле ханым янында ике сәгатьләп тә булмады кебек тоелды, чөнки ул арада инде тәрәзә капкачы ярыкларыннан көн яктысы сарка башлап, озакламый йокы бүлмәсе эченә аксыл сыек яктылык та иңгән иде.

Шул вакыт д'Артаньянның кайтырга җыена башлавын күреп, миледи аның де Вардтан ханым өчен үч алырга вәгъдә иткәнлеген исенә төшерде.

— Мин ул эшкә әзермен, тик аңарчы минем бер нәрсәгә ышанасым килә,— диде д'Артаньян.

— Нинди нәрсәгә? — дип сорады миледи.

— Сезнең мине яратуыгызга.

— Мин инде моны исбат иттем шикелле.

— Әйе, иттегез, мин дә сезгә җаным-тәнем белән бирелгәнмен.

— Рәхмәт, батыр сөйгәнем! Мин үземнең яратуымны сезгә исбат иткән кебек, сез дә миңа исбат итәрсез дип беләм, шулаймы?

— Әлбәттә,— дип җөпләде д'Артаньян,— ләкин сез, үзегез әйтмешли, мине яратасыз икән — минем өчен аз гына да курыкмыйсызмыни?

— Нәрсәдән куркыйм соң мин?

— Ничек нәрсәдән? Минем бик каты яралануым, хәтта үлүем дә ихтимал бит.

— Алай булмас, сез бик батыр егет, кылыч белән бик оста сугышасыз,— диде миледи.

— Әйтегез әле, сезнең өчен нәкъ шулай ук үч алырлык, сугышуны кирәксез итәрлек башка бер чараны яхшырак санамас идегезме сез?

Миледи, җавап бирмәстән, сөйгәненә күтәрелеп карады: иртәнге аксыл сыек таң яктысында аның зәңгәр күзләре бик сәер һәм шомлы булып күренде.

— Ихластыр, миңа калса, сез икеләнәсез кебек,— диде хатын.

— Юк, мин икеләнмим, ләкин ул бичара графны сез ташлаганнан бирле, ихластыр, бик кызганам; минемчә, сезнең мәхәббәтегездән мәхрүм булган ир кеше шундый каты җәзага тарган — аны инде тагы да җәзалау кирәк тә түгел кебек.

— Минем аңа мәхәббәтем булган дип сезгә кем әйтте? — дип сорады миледи.

— Һәрхәлдә, артык һаваланмый гына әйтә алам: сез хәзер башка кешене яратасыз,— диде егет, мөлаем бер тавыш белән,— һәм, кабатлап әйтәм, графны бик кызганам мин.

— Сез?

— Әйе, мин.

— Ә нигә кызганасыз соң сез аны?

— Чөнки бер мин генә беләм...

— Нәрсәне?

— Сезнең алда үзегез уйлаганча ук гаепле түгеллеген, дөресрәге — гаепле булмаганлыгын.

— Аңлатыбрак сөйләгез,— диде миледи, борчуга төшкән бер тавыш белән,— чөнки мин, ихластыр, сезнең болай дип ни әйтергә теләгәнегезне төшенмим.

Шулай дигәч, ул үзен кочаклап утырган д'Артаньянга күтәрелеп карады, хатынның күзләре чаткыланып ялтырый башлады.

— Мин намуслы кеше,— диде д'Артаньян, бу эшкә чик куярга теләп,— сез мине ярата башлаганнан бирле, сезнең яратуыгызга ышанганнан бирле,— мин бит сезнең яратуыгызга ышана алам, шулаймы?

— Әйе, әйе, әлбәттә... Шуннан?

— Менә шул! Минем шатлыгым-сөенечем эчемә сыймый, һәм мин бер серне ачмый түзә алмыйм.

— Сер?

— Мин сезнең яратуыгызга ышанмасам, ул серне ачмас идем. Сез мине яратасыз бит, гүзәл ярым? Дөрес бит, сез, сез мине яратасыз бит?

— Әлбәттә, яратам.

— Алайса, әйтегез әле, әгәр мин сезне артык яратуым

аркасында сезнең алда берәр гаеп эш кылган булсам, сез мине кичерер идегезме?

— Ихтимал.

Д'Артаньян, бик мөлаем елмаеп, иреннәрен милединың иреннәренә якын китерә башлаган иде дә, ханым аны этәреп җибәрде.

— Сер...— диде ул, агарынып.— Нинди сер ул?

— Бу пәнҗешәмбедә шушында, шушы бүлмәдә сез де Вард белән очрашкансыз, шулай бит?

— Мин? Юк. Андый хәлнең булганы юк,— диде миледи, катгый тавыш һәм тып-тыныч бер төс белән. Д'Артаньян бу хәлне тәгаен белмәсә, үзенең хаклыгына шикләнгән дә булыр иде.

— Алдашмагыз, гүзәл фәрештәм, барыбер файдасы юк,— диде егет, елмаеп.

— Ни дигән сүз бу? Аңлатыбрак әйтегез! Бу сүзегез белән сез мине үтерәсез!

— О, бер дә борчылмагыз, сезнең минем алда берниндн гаебегез юк, мин сезне гафу иттем инде.

— Я, шуннан, шуннан?

— Де Вард мактанырлык бер эш тә кылмады.

— Нигә? Сез бит үзегез әйттегез миңа: әлеге йөзек...

— Җаным, ул йөзек миндә. Пәнҗешәмбе кичне сезнең янда булган граф де Вард белән бүгенге д'Артаньян — икесе бер үк кеше.

Саксыз егет ханымны гаҗәпләнер, уңайсызланыр, гарьлектән бераз дулап алыр да елый башлар дип көткән иде, әмма егет бик каты ялгышты, һәм аның бу ялгышуы әллә ни озак та дәвам итмәде.

Миледи, агарынган, күзе-башы җимерелгән бер кыяфәттә урыныннан күтәрелә төшеп, д'Артаньянны бик каты күкрәгеннән этеп җибәрде дә ятагыннан сикереп торды.

Бүлмә эче яктырып беткән иде инде.

Д'Артаньян, гафу үтенмәкче булып, аның бик юка һинд тукымасыннан тегелгән пеньюарыннан тотты, миледи тартылып аның кулыннан ычкынмакчы булды. Шул чагында батист пеньюар ертылып китте дә хатынның кулбашлары ачылды, һәм д'Артаньян аның ап-ак йомры кулбашында лалә чәчкәсе сурәте күреп өнсез калды — гомергә бетми торган, палач кулы белән салынган хурлык тамгасы иде бу.

Егет, пеньюарны кулыннан ычкындырып:

— Йа раббым! — дип кычкырып куйды.

Һәм йөрәге өшегән хәлдә, өнсез-хәрәкәтсез булып, утырган җирендә катып калды.

Д'Артаньянның шулай куркуыннан миледи үзенең фаш булганлыгын аңлап алды, чөнки егет, тәгаен, бөтенесен күрде. Хәзер инде д'Артаньян аның моңарчы беркем белмәгән серен, куркынычлы серен белә иде.

Миледи ярсыган-дулаган бер хатын булып түгел, бәлки яраланган тау юлбарысы булып д'Артаньянга таба борылды.

— Җүнсез, мине кабахәт рәвештә сатуың гына җитмәгән, серемне дә белдең! Син үләчәксең! — диде миледи.

Туалеты өстендә торган инкрустацияле кечерәк бер тартма янына йөгереп барды да калтыранган куллары белән аны тиз генә ачып, алтын саплы бик юка, үткен йөзле кечкенә генә хәнҗәр алды һәм кире борылып ярым ялангач д'Артаньянга ташланды.

Белгәнебезчә, егет бик батыр булса да, милединың дәһшәтле йөзен, акайган күзләрен, агарынган яңакларын һәм кандай кызыл иреннәрен күреп, аның да йөрәгенә курку төште; ул, үзенә таба елан үрмәләгәнен күреп алган сыман, стенага табарак шуышты; тирләп юешләнгән кулына очраклы гына кылычы тиеп китүгә, аны кынысыннан суырып чыгарды.

Әмма миледи, кылычка игътибар итмәстән, караватка менеп, егеткә хәнҗәре белән кадамакчы булды, күкрәгенә кылыч очы тигәч кенә тукталды.

Шуннан соң ул кылычны кулы белән тотып алырга маташты, ләкин д'Артаньян кылычны тоттырмады, аны хатынның әле күзенә, әле күкрәгенә тери-тери, идәнгә шуып төшеп, артка, Кэтти бүлмәсенең ишегенә таба чигенергә чамалады.

Миледи исә, әллә нинди бер ерткыч ырылдаган тавышлар чыгара-чыгара, ярсып егет өстенә ташлана бирде.

Бу хәл чын дуэльгә охшый башлады һәм д'Артаньян әкренләп исенә-һушына килде.

— Бик яхшы, гүзәлем! Бик яхшы! — диде ул.— Тик, алла хакы өчен, тынычлана күрегез, югыйсә, сөйкемле битләрегезгә икенче лалә чәчкәсе төшереп куярмын.

— Кабахәт! Кабахәт! — дип ажгырды миледи.

Д'Артаньян, ишеккә таба чигенә-чигенә, һаман саклануында булды.

Алар дөбердәшкән тавышка Кэтти ишекне ачты,— миледи егеткә үрелү өчен урындыкларны аудара, д'Артаньян исә, хатыннан сакланырга тырышып, урындыкларга ышыклана иде. Шул рәвешчә саклана-саклана ишеккә якынлашырга тырышкан д'Артаньян бу минутта кыздан ике-өч адым чамасында гына иде инде. Ул ялт кына сикереп миледи бүлмәсеннән асрау кыз бүлмәсенә чыкты да шартлатып ишекне япты һәм, бөтен гәүдәсе белән ишекне терәүгә, Кэтти бикне шудырып та куйды.

Шуннан соң миледи, хатын-кызга хас булмаган бер көч күрсәтеп, ике арадагы бүлмә тактасын ватып чыгарга маташты; аннары инде, бу эшнең хәленнән килмәвен күргәч, бик яман ләгънәт сүзләре яудыра-яудыра, ишеккә хәнҗәр белән кадарга керешге, хәнҗәре хәтта ишекнең агачын тишеп-тишеп тә чыкты.

Ишекне бикләп алгач, д'Артаньян, ярым пышылдап, кызга әйтте:

— Тиз бул, тиз бул, Кэтти, йорттан чыгып китәргә булыш миңа; без аңа аңгышырга вакыт бирсәк, хезмәтчеләренә мине үтерергә кушачак.

— Шушы килеш чыгып китә алмыйсыз ич, сез бит бөтенләй ялангач дип әйтерлек,— диде Кэтти.

— Әйе шул, шулай шул,— диде д'Артаньян, ялангачлыгын хәзер генә искәреп,— нәрсә булса да кигез миңа, тиз бул. Аңла: минем исән калу-калмавым турында бара сүз.

Кэтти моны бик яхшы аңлады; егеткә тиз генә ниндидер чәчәкле бер хатын-кыз күлмәге, киң кырыйлы капор * һәм мантилья ** кигезде, аннары ялан аягына туфли кидердс дә аны баскычтан алып төшеп китте. Нәкъ вакытында чыгып өлгерделәр,— миледи кыңгыравын чыңлатып бөтен йортны аякка бастырган иде инде. Капка сакчысы капканы ачып җибәрүгә үк, миледи, ярым ялангач килеш, тәрәзәдән сузылып·

— Ачмагыз! — дип кычкырды.

## VIII

## АТОСНЫҢ БЕРНИНДИ МӘШӘКАТЬСЕЗ ГАСКӘРИ КИРӘК-ЯРАК ТАБУЫ

Чаба-чаба китеп барган егет артыннан миледи йодрыкларын селкеп янап калды. Егет китеп күздән югалуга, хатын һушыннан язып егылды.

Д'Артаньян шулкадәр әсәренгән-каушаган иде — бичара Кэттига ниләр буласын уена да китермәстән, ярты Парижны җан-фәрманга узып, Атос квартирының ишеге төбенә килеп җиткәч кенә туктады. Күңелен баскан шом, курку тойгысы, патрульләрнең кычкырып калулары, хәтта кайберләренең арттан куа да килүе, таң тишегеннән торып үз эшләре белән йөри башлаган сирәк-мирәк узгынчыларның һай-һулап кычкырып калулары аны отыры чаптыра гына төшкән иде.

Ул, ишегалдын узып, өченче катка менде дә Атосның ишеген бик каты дөбердәтергә керешге.

Йоклый-йоклый шешенеп беткән Гримо килеп ишек ачты. Д'Артаньян, аны аяктан ега язып, бүлмәгә кереп китте.

Гадәттә тавыш-тынын чыгармый торган бичара егет — бу юлы инде телгә килде.

— Әй, карале! Ни кирәк сиңа, оятсыз тәтәй, кая керәсең анда, өстерәлчек?! — дип кычкырды.

Д'Артаньян, капорын кырынрак салып, кулларын мантильясы эченнән чыгарды; аның мыегы белән ялан кылычын күргәч, бичара Гримо үз каршында бер ир кеше басып торганлыгын абайлады.

---

* Хатын-кыз баш киеме.

** Хатын-кыз кия торган кыска итәкле җиңсез япанча.

Шуннан соң инде ул моны кеше талаучы бер бәндә дип уйлап:

— Каравыл! Коткарыгыз! Каравыл! — дип кычкырырга керешге.

— Акырма, җүләр! Бу — мин, д'Артаньян, танымадыңмыни? Хуҗа әфәндең кайда? — диде егет.

— Сез — д'Артаньян әфәндеме? Түгел! — дип кычкырды Гримо.

Өстенә халат киеп, йокы бүлмәсеннән Атос килеп чыкты.

— Гримо, сез телегезне чишеп сүз әйттегез шикелле,— диде ул.

— Әфәндем, менә бит, ни...

— Тыныгыз чыкмасын!

Гримо шым булды да хуҗасына д'Артаньянны гына күрсәтте.

Атос иптәшен шундук танып алды һәм, никадәр авыр сабырлы кеше булса да, түзмәде — шаркылдап көлеп җибәрде — каршында торган бу бик әкәмәт маскарад костюмын күргәч, көлми түзү мөмкин түгел иде: аның дусты, кырын салып кына, башына капор кигән, күлмәк итәге идәнгә хәтле салынып төшкән, җиңнәрен сызганып җибәргән, йөзе бик җитди — әсәренгән, мыек очлары тырпаеп тора иде.

— Көлмәгез, дустым, ходай хакы өчен көлмәгез,— дип кычкыра төшеп әйтте д'Артаньян,— чөнки, ант әгәр, бер дә көлә торган чак түгел.

Бу сүзләрен егет шундый җитди тавыш белән, чын курку белән әйтте ки, Атос көлүеннән шундук шып туктады.

— Чыраегыз ап-ак, дустым, әллә яраландыгызмы? — диде ул, егетнең кулыннан тотып.

— Юк, яраланмадым, менә әле яңа гына минем белән бер коточкыч хәл булды. Сез үзегез генәме, Атос?

— Шайтаным алгыры. Бу вакытта кем булсын инде монда?

— Яхшы, алайса.

Шулай дигәч, д'Артаньян ашыга-ашыга Атосның йокы бүлмәсенә кереп китте.

— Я, сөйләгез,— диде Атос, үзләренә берәү дә комачауламасын дип, ишекне ябып бикләп куйды.— Король үлмәгәндер бит? Әллә кардиналны үтердегезме? Бөтенләй чыраегыз калмаган! Тизрәк сөйләгез инде, түзәр хәлем калмады минем.

— Атос, адәм ышанмаслык бер хәлне тыңларга әзер булып торыгыз,— дип, д'Артаньян, өстендәге хатын-кыз күлмәген салып ташлап, эчке күлмәгеннән генә калды.

— Башта менә бу халатны киеп алыгыз,— диде мушкетер.

Д'Артаньян халатны киде, бик нык дулкынланган-каушаган булганга, кулларын җиң эченә кертә алмый азапланды.

— Я, шуннан? — диде Атос.

— Шуннан — шул! — диде д'Артаньян, Атосның колагына

иелеп, тавышын экренәйтә төште: — Милединың кулбашына лалә чәчкәсе басканнар!

Мушкетер, йөрәгенә пуля килеп тигән кебек:

— Аһ! — дип куйды.

— Карагыз әле, сез теге хатынның үлгән булуына тәгаен ышанасызмы? — дип сорады д'Артаньян.

— Теге хатын? — дип кайтарып сорады Атос, тонык кына бер тавыш белән — д'Артаньян аның сүзен көчкә ишетеп калды.

— Әйе, бервакыт миңа Амьенда чакта сөйләгән идегез бит — шул хатын

Атос, ыһылдап, йөзе белән учларына капланды.

— Бу хатынга егерме алты-егерме җиде яшьләр чамасы,— диде д'Артаньян.

— Чәче аксыл-сарымы? — дип сорады Атос.

— Әйе.

— Гаҗәеп дәрәҗәдә ачык зәңгәр күзле, кара кашлы, кара керфеклеме?

— Әйе.

— Озын буйлы, бик ыспай гәүдәле? Сул якта өстә бер теше дә юк?

— Әйе.

— Лалә чәчкәсе зур түгел, кызгылтрак төстә, яртылаш ышкылган кебегрәк?

— Әйе.

— Сез бит аны инглиз милләтеннән дигән идегез?

— Бөтен кеше миледи ди аңа, француз милләтеннән булуы да бик ихтимал. Лорд Винтер — аның иренең абыйсы гына бит.

— Д'Артаньян, минем аны күрәсем килә.

— Сак булыгыз, Атос, сак булыгыз. Сез бит аны асып киткәнсез. Бик хәтәр хатын ул — сездән дә нәкъ шулай итеп үч кайтарачак һәм моны җиренә җиткереп эшләячәк.

— Ул хакта беркемгә дә сөйли алмаячак ул, чөнки үзен генә фаш итәчәк.

— Бөтенесен дә эшли ала ул хатын. Сез аның ачуланган чагын күргәнегез булдымы?

— Юк.

— Юлбарыс ул, тау юлбарысы! Ай, Атос дус, бик куркам мин: безнең икебездән дә бик яман итеп үч алмагае ул.

Шуннан соң д'Артаньян дустына милединың ачудан ярсып шашуларын, егетне үтерергә маташуларын — барысын-барысын сөйләп бирде.

— Сез хаклы, ант итеп әйтәм: хәзер минем җаным-гомерем бер тиен дә тормый,— диде Атос.— Бәхеткә каршы, берсекөнгә инде без Париждан чыгып китәбез, мөгаен, безне Ларошельгә җибәрерләр, без моннан киткәч инде...

— Ул сезнең дөньяда барлыгыгызны белсә, артыгыздан

җир читенә хәтле дә барачак, Атос. Ачуы-үче төшсә бер миңа гына төшсен инде.

— Ай, дустым, үтерсә дә бер дә исем китми! — диде Атос. — Әллә миңа җаным бик кадерле дип беләсезме?

— Боларның астында ниндидер бик яман бер яшерен сер бар. Беләсезме, Атос, ул хатын — кардиналның шымчысы бит, тәгаен беләм мин аны.

— Алайса, сак булыгыз инде. Теге Лондон вакыйгасы өчен кардинал сезгә таң калып сокланмаган булса, дошман итеп күрәдер. Ләкин сезне ул берничек тә ачыктан-ачык гаепли алмый, ә ачу-нәфрәт дигәнең, бигрәк тә кардиналныкы, һичшиксез, үзенең чарасын тапмый калмас, шулай булгач, сакланыгыз! Өйдән чыкканда ялгыз чыкмагыз, ашаган чакта да сак булыгыз, кыскасы, беркемгә дә, хәтта үзегезнең күләгәгезгә дә ышанмагыз.

— Бәхеткә каршы, безнең монда берсекөнгә хәтле генә яшисе калды, чөнки, армиягә баргач, безгә дошман солдатларыннан башка куркыр кеше булмас дип уйлыйм.

— Ә хәзергә мин, өйдә бикләнеп ятудан ваз кичеп, гел сезгә ияреп йөриячәкмен, — диде Атос. — Сезнең Каберчеләр урамына кайтасыгыз бар, мин дә сезнең белән барам.

— Моннан бик якын булса да, мин бу килеш кайтып китә алмыйм бит, — диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Анысы хак, — диде Атос һәм кыңгырау чылтыратты.

Бүлмәгә Гримо килеп керде.

Атос аңа, кулы белән ишарәләп кенә, д'Артаньян өенә барып, киемнәрен алып килергә кушты.

Гримо да, ишарәләп кенә, барысын да аңладым, дип җавап бирде дә китеп барды.

— Менә шулай, дустым, — дип куйды Атос, — тик әлеге мәҗәраның безгә гаскәри кирәк-ярак булдыруга берничди файдасы юк шул, ник дигәндә, сезнең бөтен киемнәрегез, ялгышмасам, миледи йортында калган бугай, ә инде ул сезнең киемнәрегезне үзегезгә кайтарып мәшәкатьләнмәс. Бәхетегезгә каршы, сезнең зәңгәр якутыгыз бар бит әле.

— Зәңгәр якут ул сезнеке, Атос дус! Аны гаиләгездә мирас булып килгән йөзек дип үзегез әйттегез бит.

— Әйе, әти аны ике мең экю акчага сатып алган булган — үзе шулай дигән иде. Әниемә туйда биргән бер бүләге булган ул, бик шәп бүләк. Шуннан соң әни аны миңа бүләк итте, ә мин, җүләр, ул йөзекне изге бер нәрсә итеп саклап тотасы урында, үз нәүбәтемдә, әлеге кабахәт хатынга бүләк иттем.

— Алайса, дустым, сез ул йөзекне кире алыгыз; сезнең өчен бик кадерле нәрсә икәнен аңлыйм мин.

— Җинаятьче кулына кереп чыкканнан соң аламмы ул йөзекне?! Алмаячакмын! Ул йөзек пычранган инде, д'Артаньян.

— Алай булгач, сатыгыз сез аны.

— Әниемнән бүләк итеп алган асылташны сатаммы! Ихластыр, изгелекне мәсхәрә итү булыр иде бу.

— Ул чагында залогка салыгыз да, һичшиксез, мең экюлап акча алырсыз. Ул кадәр акча сезнең хаҗәтләрегезгә җитеп арта, аннары инде беренче алган акчагызга ук кире кайтарып алырсыз, ростовщиклар кулы аша узгач, ул инде элекке тапларыннан чистарган булыр.

Атос елмаеп куйды.

— Искиткеч бер кеше сез, д'Артаньян дус,— диде.— Сез һәрчак көр күңелегез белән өметсезлеккә төшкән бичара бәндәләрнең рухын күтәрәсез. Була! Әйдә йөзекне залогка салабыз, тик бер шарт белән.

— Нинди шарт белән?

— Биш йөз экюсы — сезгә, биш йөзе — миңа.

— Юк ла, Атос! Миңа ул акчаның чиреге дә кирәкми — мин бит гвардиядә. Ияремне сатсам, нәкъ үземә җитәрлек акча юнәтәм. Миңа нәрсә кирәк? Планшега ат кына кирәк, менә шул. Сез минем үземнең дә йөзегем барлыгын онытасыз.

— Сезнеке минекенә караганда да кадерлерәк шикелле; һич югы, миңа шулай тоелган иде.

— Әйе, чөнки башка чарабыз калмаганда ул безне кыен хәлдән генә түгел, зур куркынычтан да коткарачак. Ул бит кыйммәтле асылташ кына да түгел, бәлки тылсымлы талисман.

— Сүзегезнең мәгънәсенә төшенеп җитмим, шулай да сезгә ышанам. Шулай итеп, минем йөзеккә, дөресрәге — сезнең йөзеккә әйләнеп кайтабыз. Я сез шуның өчен биргән акчаның яртысын үзегезгә аласыз, я мин аны Сена елгасына ыргытам. Мин, әлбәттә, берәр рәхимле балык, Поликратка китереп биргән кебек, миңа да ул йөзекне кире китереп бирер дип ышанмыйм.

— Ярый, мин риза! — диде д'Артаньян.

Шул вакытны Гримо белән Планше кайтып керделәр, хуҗа әфәндесе өчен борчылып һәм аңа ни булганын беләсе килеп, Планше киемнәрне үзе китергән иде.

Д'Артаньян киемнәрен киеп алды, Атос та киенде, аннары, ике дус әзер булып беткәч, Атос Гримога ишарәләп кенә мылтык төзәгән булып күрсәтте; Гримо, шундук стенадан мушкетын алып, хуҗа әфәндесен озата барырга әзерләнде.

Алар, бернинди хәлгә очрамыйча, Каберчеләр урамына барып җиттеләр. Ишек төбендә Бонасье әфәнде басып тора иде. Ул, беркадәр мыскыллырак төс белән көлеп, д'Артаньянга карады да:

— Ашыга төшегез, хөрмәтле өйдәш, сезне бер бик чибәр кыз көтеп тора, ә хатын-кыз, белгәнегезчә, көттергәнне яратмый,— диде.

Д'Артаньян, кычкыра төшеп:

— Кэтти ул! — диде дә атылып өскә менеп китте.

Чыннан да, ул үз бүлмәсенең ишеге төбендә Кэттины кур-

де: бичара кыз ишеккә сөялгән дә дер-дер калтыранып тора иде.

— Сез мине якларга вәгъдә иттегез, сез мине аның каһәреннән коткарырга сүз бирдегез. Исегезгә төшерегез: мине сез харап иттегез бит! — диде кыз.

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде д'Артаньян,— бер дә борчылма, Кэтти. Ә мин киткәч ниләр булды соң?

— Мин үзем дә белмим,— диде Кэтти.— Аның кычкыруына лакейлар йөгереп килде, ярсуыннан үз-үзен белештерми башлаган иде инде ул. Сезнең исемгә нинди генә каргыш-ләгънәтләр әйтмәде. Шуннан мин курка калдым: сезнең аның бүлмәсенә минем бүлмә аша кергәнегезне исенә төшереп, мине сезнең белән бер булып эш иткән дип шикләнә башласа?! Мин акчамны, иң кадерле әйберләремне алдым да чыгып качтым.

— Бичара кызый! Синең белән нишләргә соң инде? Берсекөнгә миңа китәсе.

— Теләсәгез ни эшләтегез, д'Артаньян әфәнде, миңа Париждан китәргә ярдәм итегез, Франциядән китәргә булышыгыз.

— Мин сезне Ларошельне камаган төшкә алып китә алмыйм ич инде,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Әлбәттә, алып китә алмыйсыз, ләкин сез мине берәр провинциягә, мәсәлән, туган ягыгыздагы берәр таныш ханымыгызга урнаштыра аласыз.

— Кэтти, җаным, минем туган ягымда бай ханымнар асрау тотмыйлар шул. Хәер, туктале, менә нәрсә эшлибез. Планше, Арамисны чакырып кил әле. Хәзер үк монда килсен. Аның белән сөйләшәсе сүз бар.

— Аңлыйм,— диде Атос.— Ә нигә Портос белән түгел? Минемчә, аның маркизасы...

— Портосның маркизасына киенгән чагында иренең писерләре булыша,— диде д'Артаньян, көлеп.— Аннан ары, Кэтти Аю урамында яшәргә теләми дә, шулаймы, Кэтти?

— Миңа кайда да ярый, тик мине әйбәтләбрәк яшерсеннәр дә минем кайда икәнемне беркем белмәсен,— диде кыз.

— Хәзер инде, Кэтти, без синең белән аерылышабыз, димәк, моннан соң мине көнләмәссеңдер инде.

— Д'Артаньян әфәнде, мин кайда гына булсам да, якын арадамы, ерак җирдәме, мин һәрвакыт сезне яратып яшәячәкмен,— диде Кэтти.

— Менә кайда икән ул сүрелмәс мәхәббәт, шайтан алгыры!..— дип куйды Атос.

— Мин дә, мин дә сине гел яратып яшәячәкмен, тыныч бул,— диде д'Артаньян.— Тик менә нәрсә, бер соравыма җавап бир әле, минем өчен бик кирәк ул. Беркөнне төнлә урланган бер яшь хатын турында синең берәр нәрсә ишеткәнең булмадымы?

— Туктагыз әле... Ай аллам, сез тагын шул хатынны да яратасызмы әллә?

— Юк, аны минем дусларымнан берсе ярата. Менә бу, шушы, Атос ярата.

Атос, елан өстенә баскандай, коты чыккан бер кыяфәт белән:

— Мин! — дип кычкырып җибәрде.

— Соң, әлбәттә, син! — диде д'Артаньян, Атосның кулын кысып.— Ул бичара Бонасье ханымның язмышы өчен барыбыз да ничек борчылганыбызны бик яхшы беләсең бит син. Хәер, Кэтти бу турыда берәүгә дә әйтмәячәк. Шулаймы, Кэтти? Беләсеңме, җаным,— дип сүзендә дәвам итте д'Артаньян,— син миңа килгәндә ишек төбендә иләмсез бер адәм күргәнсеңдер,— әлеге ханым — шуның хатыны ул.

— Йа раббым! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды Кэтти.— Шуны исемә төшердегез! Мин ул кешедән бик куркам! Мине танып кына кала күрмәсен!

— Ничек ул — танып кала күрмәсен? Димәк, моңарчы синең ул кешене күргәнең булган инде?

— Ул ике тапкыр миледи янына килде.

— Менә бит! Кайчан килде?

— Унбишме-унсигезме көн элек.

— Әйе, әйе, нәкъ шулай.

— Кичә кич тагын килеп китте.

— Кичә кич?

— Әйе, сезгә кадәр бер минут кына алдан.

— Атос дус, безне шымчылар чолгап алган! Ул сине танып калгандыр дип уйлыйсыңмы, Кэтти?

— Мин, аны күргәч, капорымны маңгаема ук төшергән идем дә соңгарак калдым бугай.

— Атос, барыгыз, аска төшеп менегез әле, миңа караганда сездән азрак шикләнә ул; һаман ишек төбендә басып тора микән әле — шуны карагыз.

Атос аска төшеп, озакламый әйләнеп тә менде.

— Юк ул, ишеге дә йозаклы,— диде.

— Бүген күгәрченнәрнең ояларына кайтканлыгын әйтергә киткәндер.

— Ул чагында очтык без моннан, Планшены гына калдырыйк, соңыннанниләр булганын безгә әйтер ул,— диде Атос.

— Торып тор! Ә Арамис белән нишлибез? Аны чакыртып кеше җибәрдек бит.

— Дөрес анысы, Арамисны көтик.

Нәкъ шул минутта Арамис та килеп керде.

Аңа бөтен хәлне сөйләп бирделәр, аның югары дәрәҗәле танышларыннан Кэттига урын табарга кирәклеген аңлаттылар.

Арамис беравык уйланып торды да, кызарынып китеп:

— Д'Артаньян, бу эш белән мин сиңа чыннан да файда итәрмен микән соң? — дип сорады.

— Гомерем буе сезгә рәхмәт укырмын.

— Алайса болай: де Буа-Траси миннән үзенең бер дус хатыны өчен,— кайдадыр провинциядә яши бугай ул,— шуның өчен ышанычлы бер асрау кыз табуымны үтенгән иде, әгәр сез, д'Артаньян, ышандырсагыз...

— Һай, әфәндем! — диде Кэтти,— ихластыр, миңа Парижтан китәргә мөмкинлек биргән ханымга гомерем буе тугрылыклы булып калыр идем.

— Ул чагында җайларбыз,— диде Арамис.

Өстәл янына утырып хат язды да аны, йөзек кашы белән печатьләп, Кэттига бирде.

— Хәзер инде, җаным, үзең беләсең, монда калу безнең өчен дә, синең өчен дә куркынычсыз булмас, шуңа күрә безгә аерылышырга кирәк. Киләчәктә без синең белән очрашырбыз әле,— диде д'Артаньян.

— Белеп торыгыз: без кайчан гына һәм кайда гына очрашасы булсак та, мин сезне хәзерге шикелле үк яратачакмын,— диде Кэтти.

Д'Артаньян Кэттины озатырга дип баскычка чыгып киткәч, Атос:

— Уенчы анты,— дип куйды.

Бераздан инде өч егет сәгать дүрттә Атос өендә очрашырга сүз куешып аерылыштылар. Планшега йортны сакларга кушып калдырдылар.

Арамис өенә кайтып китте, Атос белән д'Артаньян исә зәңгәр якутны залогка салырга киттеләр.

Гасконь егете әйткәнчә, алар, бернинди кыенлыксыз йөзекне залогка салып, өч йөз пистоль акча алдылар. Ул гына да түгел, ростовщик, әгәр йөзекне бөтенләйгә сатсагыз, моның өчен биш йөз пистоль акча бирәм, чөнки бу якут миндәге бер колак алкасына бик охшаган, диде.

Атос белән д'Артаньянга, үз эшләрен яхшы белүче өлгер солдатларга, мушкетерга кирәкле гаскәри кирәк-ярак юнәтү өчен өч сәгать вакыт та җитте. Өстәвенә, Атос киң күнелле, күндәм бер кеше иде. Әгәр әйбер үзенә ошаса, ул, сатулашып та тормастан, сораган хакын шундук чыгарып түли иде. Д'Артаньян бу хакта аңа әйтеп тә караган иде дә Атос, елмаеп, аның җилкәсенә кулын гына салды, һәм шуннан инде д'Артаньян үзенә, ягъни ярлы бер Гасконь дворянына, болай сатулашу килешсә дә, үзен принц кебек тоткан кешегә бер дә килешми икәнлеген төшенде.

Мушкетер үзе өчен бер дигән Андалузи аты сатып алды — борын тишекләреннән ялкын бөркеп торган матур нечкә торыклы, алты яшьләр чамасындагы, сумала төсле чем-кара бер ат иде ул. Атос атны карап-тикшереп чыккач, бер кимчелеген дә тапмады. Атка мең ливр бәһа сорадылар.

Ихтимал, Атос аны арзангарак та төшерә алган булыр иде

дә, д'Артаньян барышник белән сатулашып торган арада, Атос йөз пистольне санап өстәлгә чыгарып та салган иде инде.

Гримога дип, өч йөз ливрга, карсаграк таза бер Пикардия аты сатып алдылар.

Ләкин Атос бу атка ияр һәм Гримога корал сатып алгач, аның йөз илле пистоль акчасыннан бер тиен дә калмады. Д'Артаньян дустына, минем өлештән алып тор, соңыннан кайтарырсың, дип әйтеп карагач, Атос җилкәсен генә сикертте.

— Зәңгәр якутны бөтенләйгә сатсак, ростовщик күпме бирәм дип әйткән иде әле? — дип сорады ул.

— Биш йөз пистоль.

— Ягъни, ике йөз пистольгә артыграк. Йөз пистоле — сезгә, йөзе — миңа. Дустым, бу бит үзе бер зур байлык, барыгыз, ростовщикка барып кайтыгыз.

— Ничек ул?! Сез нимени...

— Чынлап, д'Артаньян, ул йөзек бик күңелсез нәрсәләрне исемә төшереп торыр иде. Аннан ары, аны кире кайтарып алыр өчен безнең беркайчан да өч йөз пистоль акчабыз булмаячак, шуңа күрә без бу эштә ике мең ливр акчаны бушка әрәм итәбез. Ростовщикка әйтегез: йөзек — сезнеке, диегез дә ике йөз пистоль акчаны монда алып кайтыгыз.

— Яхшылабрак уйлагыз, Атос.

— Безнең заманда кулда акча булу кыйммәт, шуның өчен корбан бирә белергә дә кирәк. Барыгыз, д'Артаньян, барыгыз. Гримо үзенең мушкеты белән сезне озатып кайтыр.

Ярты сәгатьтән соң д'Артаньян, юлда бернинди маҗараларга очрамыйча, ике мең ливр акча алып кайтып та җитте.

Шул рәвешчә, Атос үзенең хуҗалыгыннан бөтенләй исендә-уенда да булмаган акча тапты.

## IX

## ТӨШТӘ ГЕНӘ КЕБЕК

Шулай итеп, дүрт дус Атос фатирына җыелдылар. Гаскәри кирәк-ярак юнәтү кайгысыннан инде алар котылганнар һәм хәзер һәркайсының чыраенда эчке яшерен борчулары гына чагыла, чөнки бәхетнең һәр минуты киләчәккә билгесез бер борчу саклый иде.

Д'Артаньян исеменә ике хат тотып, кинәт Планше килеп керде.

Хатның берсе кечкенә, озынча, нәфис,— яшел балавызга матур печать сугылган, печатендә томшыгына яшел ботак кабып очып барган күгәрчен сурәте төшерелгән иде.

Икенчесе дүрт почмаклы зур бер хат, хатның тышына герцог-кардинал хәзрәтләренең дәһшәтле гербы төшерелгән иде.

Кечкенә хатны күрүгә д'Артаньянның йөрәге сөенечтән сулкылдап тибәргә кереште: бу хатның кем тарафыннан язылган булуын ул таныды шикелле. Дөрес, әлеге кешенең язуын егет бер генә тапкыр күргән булса да, хәтеренә бик нык сеңеп калган иде.

Шулай итеп, д'Артаньян кечкенә хатны алды да тиз генә ачып укырга кереште. Болай дип язылган иде анда:

«Алдагы чәршәмбе көнне кичке сәгать алты белән җиде арасында Шайога бара торган юлда йөренгәләп, узгынчы кареталарга игътибар белән күз салгалагыз, әмма, үз гомерегез һәм сезне сөйгән кешеләрнең гомере кадерле дисәгез, бер сүз дә эндәшмәгез, сезгә бер күз салып китү өчен генә дә үзен зур куркыныч астына куючы кешене таныганлыгыгызны белгертерлек хәрәкәт-мазар ясамагыз».

Имзасы куелмаган иде.

— Тозак бу, д'Артаньян, бармагыз,— диде Атос.

— Миңа калса, мин бу язуны таныйм шикелле,— диде д'Артаньян дустының сүзенә каршы.

— Охшатып язган булулары да ихтимал бит,— диде Атос,— елның бу вакытында Шайо юлында кичке сәгать алты-җидедә берничди җан әсәре булмый. Анда бардың ни дә, Бонди урманына бардың ни — икесе бер.

— Әгәр бергәләп китсәк? — диде д'Артаньян.— Шайтаным! Дүртебезне берьюлы кабып йотмаслар ич. Өстәвенә, дүрт хезмәтчебез, атларыбыз, коралларыбыз бар.

— Атларыбызны, дирбия-коралларыбызны сынап карарга да җай булыр,— дип куйды Портос.

— Бу хатны әгәр хатын-кыз язган булса, ул хатын үзен күрүләрен теләмәсә, ул чагында сез аның абруен гына төшерәчәксез, д'Артаньян, анысын да уйлагыз. Дворян кешегә килешә торган эш булмас,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Без арттарак калырбыз, д'Артаньян карета янына үзе генә барыр,— диде Портос.

— Анысы шулай да, җан-фәрманга чаптырып килгән каретадан пистолет белән атып китү дә бик ансат бит.

— Һи! — диде д'Артаньян.— Пулясы яннан гына үтеп китә. Аннары без каретаны куып житәбез дә эчендәге кешеләрен үтереп бетерәбез. Ни дисәң дә, дошманнарыбыз кими төшәр.

— Ул дөрес әйтә. Мин сугышу яклы. Коралларыбызны сынап-тикшереп карарга кирәктер ләбаса! — диде Портос.

— Ярый соң, андый кәеф эшне дә эшләп карыйк,— диде Арамис, гадәтенчә җиңелчә, ваемсызрак бер тон белән.

— Әфәнделәр,— дип эндәште д'Артаньян,— сәгать бишенче ярты булган инде, Шайо юлына сәгать алтыга чак-чак барып житешәчәкбез.

— Өстәвенә, бик соң чыксак, безне беркем күрмәячәк, анысы инде бигрәк тә үкенечле булыр иде. Шулай итеп, юлга җыенабыз, әфәнделәр,— диде Портос.

— Сез бит икенче хатны оныттыгыз,— диде Атос.— Хәлбуки, печатена караганда, ачмый калдыра торган хат булмаска тиеш. Ихластыр, д'Артаньян дус, бу хат мине әле сез бик кадерләп кенә куеныгызга яшергән хат кисәгенә караганда күбрәк борчый.

Д'Артаньян кызарынып китте.

— Яхшы! Карыйк алайса, әфәнделәр, ни кирәк икән миннән кардинал хәзрәтләренә,— диде егет.

Хатны ачып, мондый юлларны укыды:

«Король гвардиясе, Дезэссар ротасыннан д'Артаньян әфәнде бүген кичке сәгать сигезгә кардинал сараена чакырыла.

*Ла Удиньер,*
гвардия капитаны».

— Шайтан алгыры! Менә бу күрешү тегесеннән, беренчесеннән, хәтәррәк булачак инде,— дип куйды Атос.

— Берсенә барып кайтам да аннары икенчесенә китәм,— диде д'Артаньян.— Берсе сәгать җидегә, икенчегә сигезгә билгеләнгән. Вакыт — икесенә дә җитәрлек.

— Һе! Мин бармас идем,— диде Арамис.— Илтифатлы кавалер дамасы билгеләгән очрашуга бармый кала алмый, ә менә акыллы дворян, кардинал хәзрәтләре чакырганга бармаса да, сылтау таба ала, үзен анда кунакка чакырмыйлар дип уйларлык нигезе булса бигрәк тә.

— Мин Арамисның фикеренә кушылам,— диде Портос.

— Әфәнделәр, мин бер тапкыр де Кавуа әфәнде аркылы кардинал хәзрәтләреннән мондый чакыру хаты алган идем инде,— диде д'Артаньян.— Мин ул хатка әһәмият бирмәдем, һәм икенче көнне үк минем өчен зур бер бәхетсезлек булды: Констанция юкка чыкты. Ни булса да барам.

— Карарыгыз катгый икән, барыгыз,— диде Атос.

— Һи, исегез киткән! Сез коткарырсыз мине аннан,— диде д'Артаньян.

Арамис белән Портос үз-үзләренә бик ышанган һәм ансат кына эш итеп караган сыман тавыш белән беравыздан җавап кайтардылар:

— Әлбәттә, әлбәттә, коткарабыз, тик менә берсекөнгә юлга чыгасыбыз бар, шуңа күрә аңарчы ул Бастилиядән сакланыбрак тору хәерлерәк булмас микән,— диделәр.

— Әйдәгез, болай итик,— диде Атос,— без аны бүген кич ялгыз калдырмыйк, кардинал сараена барганда һәркайсыбыз, өчәр мушкетер ияртеп килеп, аерым-аерым капка төпләренә сакка басыйк. Аннан берәр төрле ябык карета чыкканы күренсә, аз гына шикле тоелса да, без аңа һөҗүм итәбез. Кардиналның гвардиячеләре белән күптән чәкәләшкән юк бит инде, де Тревиль әфәнде безне үлгән җаннар дип саный торгандыр.

— Валлаһи, Атос, сез полководец булып тугансыз,— диде Арамис.— Әфәнделәр, бу план хакында сез нәрсә диярсез?

— Бик шәп план! — дип бертавыштан җавап кайтарды егетләр.

— Шулай итеп, мин хәзер казармага йөгерәм дә иптәшләрне сәгать сигезгә әзер булыгыз дип искәртеп куям,— диде Портос.— Кардинал сарае каршындагы мәйданда очрашырга дип сөйләшәбез. Ә хәзергә сез хезмәтчеләрегезгә атларыгызны иярләргә куша торыгыз.

— Минем атым юк шул,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.— Дөрес анысы, де Тревиль әфәндедән ат сорап тора алам алуын.

— Кирәкми, минем бер атны алырсыз,— диде Арамис.

— Сезнең атыгыз ничәү соң? — дип сорады д'Артаньян.

— Өчәү,— диде Арамис, елмаеп.

— Дустым, минем уемча, Франция белән Наварраның барлык шагыйрьләре дә атка сезнең чаклы бай түгелдер,— диде Атос.

— Карагыз әле, Арамис дус, өч ат белән нишләргә икәнлеген сез үзегез дә белеп бетермәссездер әле. Ни өчен берьюлы өч ат сатып алганыгызны мин берничек тә аңлый алмыйм.

— Хикмәте шул: өченче атны мина бүген иртән ливрейсыз гына бер лакей китерде, үзенең кем лакее икәнен әйтергә теләмәде, бай әфәндем шулай кушты, диде...

— Яки байбикәсе кушкандыр,— диде д'Артаньян, аны сүзеннән бүлдереп.

— Анысының әһәмияте юк...— диде Арамис, кызарынып.— Байбикәм бу атны сезнең абзарыгызга китерергә кушты, ди, ә үзен кем җибәргәнлеген әйтми.

— Юк, мондый хәлләр фәкать шагыйрьләр белән генә була торгандыр,— дип куйды Атос, җитди генә итеп.

— Ул чагында болай итик,— диде д'Артаньян.— Сез үзегез кайсы атыгызга атланасыз? Сатып алганынамы, әллә бүләк ителгәненәме?

— Әлбәттә, бүләк ителгәненә. Аңлыйсыңдыр инде, д'Артаньян, мин бит ул кадәр ихтирамсызлык күрсәтә алмыйм...

— Ат бүләк итүче билгесез кешегә,— дип өстәп җибәрде д'Артаньян.

— Яки ат бүләк итүче серле ханымга,— дип тәзәтебрәк әйтте Атос.

— Димәк, үзегез сатып алган ат хәзер сезгә кирәк түгел?

— Шулай дип әйтерлек.

— Сез аны үзегез сайлап алдыгызмы?

— Бик җентекләп карап алдым. Үзегезгә мәгълүм, җайдакның исәнлеге һәрвакыт диярлек аның атына бәйле!

— Алайса, сез аны үзегез түләгән хакка сатыгыз миңа.

— Мин үзем дә аны сезгә тәкъдим итәргә җыена идем, д'Артаньян дус, аннары, кирәге калмагач, кайтарып илтерсез.

— Күпмегә төште ул сезгә?

— Сигез йөз ливрга.

— Менә сезгә ике бәрабәрле кырык пистоль, дустым,— диде д'Артаньян, кесәсеннән акчалар чыгарып.— Поэмаларыгыз өчен сезгә нәкъ шушындый тәңкәләр түләгәннәрен беләм мин.

— Сез шундый баймыни? — диде Арамис, гаҗәпләнеп.

— Баймын, бик баймын, дустым!

Шулай дигәч, д'Артаньян кесәсендә калган акчаларын чылтыратып күрсәтте.

— Иярегезне мушкетерлар казармасына җибәрегез дә башка атлар белән бергә сезнекен дә китерерләр.

— Бик яхшы. Тик озакламый сәгать биш була бит инде, ашыгырга кирәк.

Бер унбиш минуттан соң Феру урамы башында бер дигән испан айгырына атланган Портос күренде. Аның артыннан тәбәнәк кенә Оверн атында Мушкстон килә, аның да аты бик чибәр иде. Портосның шатлык-сөенече, горурлыгы бөтен кыяфәтенә чыккан иде.

Алар белән бер үк вакытта урамның икенче башында бик шәп инглиз чабышкысына атланган Арамис күренде, аның артыннан Руан атында Базен килә, ул, тезгененнән җитәкләп, таза, көчле Мекленбург айгыры алып килә: монысы д'Артаньянга дигән ат иде.

Ике мушкетер ишек төбендә очраштылар: Атос белән д'Артаньян аларга тәрәзәдән карап торалар иде.

— Ах, шайтан алгыры! Атыгыз искиткеч шәп икән, Портос дус,— диде Арамис.

— Әйе шул,— диде Портос,— бу миңа башта ук китереләсе ат иде; иренең ахмакларча шаяртуы аркасында моны башкага алыштырырга булганнар, әмма соңыннан ире җәзасын алды, мин дә бөтен яктан канәгать булдым.

Озакламый хуҗа әфәндесенең атын җитәкләгән Гримо белән Планше да күренде; д'Артаньян белән Атос, өйдән чыгып, атларына атландылар да дүрт дус юлга кузгалдылар. Атос — хатыны аркасында юнәткән атка, Арамис — сөяркәсе ярдәмендә, Портос — прокурор хатыны булышлыгы белән, д'Артаньян исә барлык сөяркәләрдән дә яхшырак булган форсат дигән нәрсә аркасында тапкан атка атланганнар.

Артларыннан хезмәтчеләре ияргән иде.

Портос уйлаганча, бу кавалькада бик көчле тәэсир калдырырлык иде, әгәр дә Кокнар ханым сөлектәй испан айгырына атланып алган сөйгән егетенең шулкадәр мәһабәт бер кыяфәттә баруын күрсә, иренең акча сандыгын талавына тамчы да үкенмәс иде.

Лувр янында дүрт дуска Сен-Жерменнан кайтып килгән де Тревиль әфәнде очрады; егетләрне туктатып, ул аларның бик шәп атларына, корал-дирбияләренә сокланды, һәм ул арада болар тирәсенә берничә йөз «ачык авыз» да җыелып өлгерде.

Д'Артаньян, бу очрашудан файдаланып, де Тревиль әфәндегә зур кызыл печать белән герцог гербы төшерелгән хат турында әйтте; билгеле инде, икенче хат турында ләм-мим сүз ычкындырмады.

Де Тревиль әфәнде дүрт дусның ниятен хуп күрде һәм, д'Артаньян иртәгә аның янына килеп чыкмаса, егет кайда гына булмасын, аны эзләп табу чарасын үзем күрермен, дип ышандырды.

Шул вакыт Самаритянкадагы сәгать алтыны сукты; дуслар, бик ашыгыч күрешәсе кешебез бар дип, де Тревиль әфәндедән гафу үтенделәр дә саубуллашып китеп бардылар.

Атларын кушаякка чаптырып, Шайо юлына чыктылар; инде кичке караңгы төшә башлаган, тегеләйгә дә, болайга да экипажлар үткәләп тора иде; үзеннән берничә адымда гына торган дусларының сагы астында, д'Артаньян узып баручы кареталарның эченә күз салгалады, ләкин бер генә дә таныш йөз күрмәде.

Ниһаять, унбиш минутлап көткәннән соң, тәмам караңгыланып беткәч, Севр ягыннан бер карета килеп чыгып, тиз генә бирегә таба якынлаша башлады; күрешү турында хат җибәргән ханымның нәкъ шушы каретада булырга тиешлеген д'Артаньянның күңеле ничектер алдан ук сизенде, һәм егет, йөрәгенең тарсылдап тибә башлаганын тоеп, гаҗәпләнеп куйды. Шул минутта ук диярлек карета тәрәзәсеннән бер хатын-кыз башы күренде; аның ирен турысына куйган ике бармагы, бер сүз дә эндәшмә, мин сине үбәм, дигәнне аңлата иде; д'Артаньян сөенеченнән әкрен генә аһылдап куйды: әлеге хатын — дөресрәге, төштә генә күргән сыман бер сын,— чөнки карета яшен тизлеге белән елт итеп кенә үтеп китте,— Бонасье ханым иде.

Алдан кисәтеп куелган булуына да карамастан, д'Артаньян ихтыярсыздан атын кушаяклатып чаптырып китте һәм берничә секундта каретаны куып та җитте, ләкин каретаның тәрәзәсе инде пәрдә белән бөтенләй томалап куелган иде. Шулай итеп, төштәге сын юкка да чыкты.

«Үз гомерегез һәм сезне сөйгән кешеләрнең гомере кадерле дисәгез, берниндиҗ хәрәкәт-мазар ясамагыз һәм берни күрмәгәнгә салышыгыз» дигән кисәтү шунда гына д'Артаньянның исенә төште.

Ул, үзеннән бигрәк әлеге бичара хатын өчен куркып, туктап калды; хатын, аның белән күрешергә теләп, үзен зур куркыныч астына куйган, күрәсең.

Карета шул ук тизлеге белән китә барды; аннары ул җилдереп Парижга барып керде дә күздән югалды.

Д'Артаньян, нәрсә уйларга да белмичә, аптырап, баскан урынында катып калды. Әгәр бу хатын Бонасье ханым булса, аның Парижга кайтуы булса, җилдереп барган карета тәрәзәсеннән генә күреп, күзгә-күз карашып кына калу, үпкән

булып бармак белән генә ым күрсәтү нигә кирәк? Әгәр бу хатын ул булмаса,— алай булуы да ихтимал бит, чөнки ярым караңгыда ялгышу бик мөмкин,— әгәр бу хатын ул булмаса, бу нәрсә аның үзенә каршы оештырылган интриганың башлангычы түгелме, аның дошманнары егетнең беркемнән яшермичә яратып йөргән хатынын җим итеп кенә файдаланмаганнармы?

Д'Артаньян янына юлдашлары килеп җитте. Алар өчесе дә карета тәрәзәсеннән бер хатын-кызның башын чыгарып каравын бик ачык күреп калганнар, тик Атостан башкалары Бонасье ханымны күреп-танып белми иде. Атос уенча, бу хатын шул үзе булган, ләкин ханымның чибәр йөзенә д'Артаньян шикелле текәлеп карамаганлыктан, Атос карета эчендә икенче бер кешенең башын — ир кеше башын да күреп калган.

— Алай булса, алар аны бер төрмәдән икенчесенә күчерәләрдер,— диде д'Артаньян.— Ул бичараны нишләтмәкче булалар икән инде? Мин аны тагын күрә алырмынмы икән?

— Дустым,— дип эндәште Атос, җитди бер тавыш белән,— бел: бу дөньяда бары тик үлгән кешеләр белән генә күрешеп булмый. Без инде анысын бераз беләбез, шулай бит? Менә шул, сөйгәнегез исән булса, әлеге каретада күреп калган хатын ул булса, сез аны иртәме-соңмы барыбер эзләп табарсыз. Бәлки, моның,— диде үзенә хас күңелсез бер тавыш белән,— бәлки, моның сез теләгәннән иртәрәк булып куюы да ихтимал.

Сәгать сигезенче яртыны сукты, карета хатта әйтелгәннән егерме минут соңрак үтеп китте. Д'Артаньянга дуслары тагын бер визит ясыйсы барлыгын исенә төшерделәр, аннан баш тартырга да соң түгел әле дигән киңәш тә әйттеләр.

Ләкин д'Артаньян бер үк вакытта үзсүзле дә һәм кызыксынучан да бер егет иде. Ул, кардинал сараена барып, кардинал хәзрәтләренең ни әйтергә теләгәнен белеп кайтам, дип күңеленә беркетеп куйган, аның бу карарын берничек тә үзгәртеп булырлык түгел иде.

Алар Сент-Оноре урамына килеп җиттеләр һәм кардинал сарае мәйданында үзләре чакырган унике мушкетерны очраттылар. Болар бу тирәдә иптәшләре кайтканны көтеп йөриләр иде. Шушында очрашкач кына аларга эшнең асылын аңлатып бирделәр.

Данлыклы король мушкетерлары полкында д'Артаньянны бик яхшы беләләр; бөтенесе дә киләчәктә бу егетне полкның мушкетеры булачак дип уйлый һәм аңа алдан ук үзләренең бер иптәшләре итеп карый башлаганнар иде. Шул сәбәпле әлеге мушкетерларның һәркайсы чакырылган эшкә катнашырга бик риза булды; өстәвенә бит, кардиналга һәм аның кешеләренә усаллык эшләү мөмкинлеге дә бар, ә андый эшкә инде бу дворяннар һәрвакыт әзер иде.

Атос аларны өч отрядка бүлеп, берсен үз җитәкчелегенә алды, икенчесен Арамис карамагына, өченчесен Портоска тап-

шырды, шуннан соң һәр отряд сарай янына аерым капка каршысына урнашты.

Д'Артаньянга килгәндә исә, ул батыр бер кыяфәт белән олы ишектән сарайга кереп китте.

Артында зур ярдәм барлыгын белеп торса да, киң баскычтан менеп барган чагында егетнең күңеле бигүк тыныч түгел иде. Аның миледига карата кылган гамәле хыянәткә охшап тора, д'Артаньян исә бу хатын белән кардинал арасында политикага бәйләнешле ниндидер мөнәсәбәтләр бар дип шикләнә; моннан тыш, егет тарафыннан бик каты яралап ташланган де Вард та кардинал хәзрәтләрен яклаучы бер кеше, ә кардинал хәзрәтләре үзенең дошманнары өчен дәһшәтле бер кеше булса, дусларын бик ярата икәнлеген д'Артаньян белә иде инде.

«Әгәр де Вард кардиналга безнең теге чәкәләшү турында әйткән булса (әйтми калмагандыр), әгәр ул минем кем икәнемне танып калган булса (анысы да бик ихтимал), ул чагында инде мин үземне беткән бер кеше дип санарга тиешмен,— дип уйланды д'Артаньян, башын чайкап.— Алайса, кардинал нигә шушы көнгә хәтле көтте икән соң? Нигә икәне аңлашыла — миледи, үзенә бик килешә торган ялган-сагышлы бер кыяфәткә кереп, кардиналга минһәп зарланып сөйләгән дә, шушы соңгы җинаять инде җитеп ашарлык булган.

«Бәхеткә каршы,— дип күңеленнән сөйләнә бирде д'Артаньян,— аста минем яхшы дусларым сакта тора, алар мине төрмәгә җибәртмәсләр, сугышып булса да алып калырга тырышырлар. Тик де Тревиль әфәнденең бер рота мушкетеры гына кардинал чаклы кардиналга каршы сугыша алмый шул — кардинал бөтен Франция гаскәрләрен үз кулында тота, аның каршында королеваның берниндп көче юк, король исә ихтыярсыз. Д'Артаньян дус, син үзең батыр егет, бик шәп сыйфатларың бар, әмма сине хатын-кыз харап итәчәк!»

Күңеленнән әнә шундый бик ямьсез нәтиҗә ясап, егет алгы бүлмәгә барып керде дә теге хатны хезмәтчегә бирде. Хезмәтче аны кабул итү залына алып керде, ә үзе сарайның эченә китеп югалды.

Кабул итү залында кардиналның биш-алты гвардиячесе бар иде. Җюссакны яралаган д'Артаньянны күргәч, алар әллә ничек сәер генә елмаеп егеткә карадылар.

Аларның бу елмаюлары д'Артаньянга шомлы бер билге булып тоелды; шулай да Гасконь егетен алай ансат кына куркытып булмый иде, дөресрәге — үз провинциясе кешеләре кебек бик горур булганга, күңелендә кузгалган курку-өркү шикелле кичерешләрен кешеләргә сиздерергә яратмый иде егет; шуңа күрә ул гвардиячe әфәнделәр янынан горур бер кыяфәт белән атлап узды да, бөеренә таянып, беркадәр мәһабәт позада, үзен чакыруларын көтеп тора башлады.

Хезмәтче кире чыгып, д'Артаньянга үз артыннан керергә

ишарәләде. Артта гвардиячеләр чыш-пыш сөйләшә башлаган кебек булдылар.

Ул коридорны узды, аннары зур бер зал аша үтте дә китапханәгә, өстәл катында нидер язып утырган бер кеше янына барып керде.

Хезмәтче аны түргәрәк уздырды һәм ләм-мим сүз әйтмичә чыгып та китте.

Башта егет үзен ниндидер җинаять эшен тикшереп-өйрәнеп утыручы бер судья каршына килеп эләктем дип уйлаган иде, озакламый өстәл янындагы кешенең язып утыруын, дөресрәге, бармаклары белән иҗекләр санап, тигезле-тигезсез юлларны төзәтеп утыруын искәрде. Каршысындагы кеше шагыйрь икән дип уйлады. Беравыктан шагыйрь дигәнс тышына «Мирам, биш пәрдәле трагедия» дип язылган кульязмасын япты да башын күтәреп егеткә карады.

Д'Артаньян шунда гына кардиналны таныды.

## X

## КАРДИНАЛ

Кардинал терсәге белән кульязмага таянып, яңагын кулына куйды да беравык егеткә текәлеп карап торды. Кардинал Ришельедәге кебек сынап карый торган үткен күз беркемдә дә юк иде, шуңа күрә д'Артаньян бөтен тәне өшеп-туңып киткәндәй хис кылды үзен.

Шулай да тыштан моны сиздермәде, эшләпәсен кулына тоткан килеш, артык масаймыйча һәм бигүк шүрләп тә төшмичә, кардинал хәзрәтләренең сүз башлаганын көтте.

— Әфәндем, Беарннан килгән д'Артаньян сез буласызмы инде? — диде аңа кардинал.

— Әйе, галиҗәнап,— дип җавап кайтарды егет.

— Тарбта һәм аның тирәсендә д'Артаньяннар ыруының берничә тармагы бар. Сез шуларның кайсысыннан буласыз? — дип сорады кардинал.

— Король хәзрәтләренең атасы бөек король Һенрих белән бергә динебез өчен сугышларга катнашкан д'Артаньянның улы булам мин.

— Менә, менә. Димәк, моннан җидеме-сигезме ай элек, туган җирегезне ташлап, башкалага бәхет эзләп килгән егет сез буласыз?

— Әйе, галиҗәнап.

— Сез Мёнг каласыннан да узгансыз, шунда сезнең белән бер мәҗара да булган, ниләр булганын хәтерләмим инде, кыскасы, бер мәҗара булган.

Д'Артаньян:

— Галиҗәнап, минем белән шундый хәл булган иде...— дип сөйли башлаган иде дә, кардинал, мин ул вакыйганы сездән

яхшырак беләм дигән сыман бер төс белән елмаеп, егетне сүзеннән бүлдерде:

— Кирәкми, кирәкми,— диде.— Кесәгездә үзегезне де Тревиль әфәндегә тәкъдим иткән хат та булган, шулаймы?

— Әйе, бар иде шул, галиҗәнап, Мёңгта нәкъ әнә шул хәлгә килеп эләккәч...

— Хат югалган,— дип сүзне дәвам иттерде кардинал.— Әйе, беләм мин аны. Шулай да де Тревиль әфәнде — кешеләрне бер күрүдә таный белүче бик оста физиономист, ул сезне, киләчәктә мушкетерлар сафына басарсыз дигән өмет белән, кияве Дезэссар ротасына урнаштырган.

— Сез бик мәгълүматлы икәнсез, галиҗәнап,— диде д'Артаньян.

— Шуннан бирле сезнең бик күп төрле маҗараларыгыз булды: беркөнне, башка бер урында буласы чакта, Картезиан монастыре артында йөрдегез; аннары дусларыгыз белән Форжга шифалы суга дип сәяхәт кылдыгыз; дусларыгыз юлда тоткарланып калды, сезгә килгәндә исә, сез юлыгызны дәвам иттердегез. Монысы бик аңлашыла: Англиядә сезнең эшләрегез бар иде.

Д'Артаньян, шаккатып:

— Галиҗәнап, минем анда баруым...— дия башлаган иде дә кардинал аны сүзеннән бүлдерде:

— Ауга баргансыздыр — Виндзоргамы, башка җиргәме, анысында кешенең эше юк. Мин боларны беләм икән, минем вазифам бөтенесен дә белеп торырга куша. Шуннан әйләнеп кайткач, сезне бик олуг бер ханым кабул иткән, ул биргән бүләкне саклавыгызны күреп мин бик сөенәм.

Д'Артаньян королева бүләк иткән йөзеген тиз генә тотты да кашы белән эчкә таба борып куйды, ләкин эш узган иде инде.

— Шул вакыйгадан соң икенче көнне сезнең янга Кавуа барды,— дип сүзендә дәвам итте кардинал,— сезнең сарайга килеп чыгуыгызны үтенде. Сез аның янына килмәдегез һәм шуның белән хаталык кылдыгыз.

— Галиҗәнап, сез кардинал хәзрәтләренең ачуын китергәнмендер дип курыктым мин.

— Ни өчен сез минем ачуымны китерерсез икән соң, әфәндем? Башлыгыгыз кушканны сез башка берәүгә караганда остарак һәм батыррак итеп үтәгән өченме? Бары тик мактау гына ишетәсе урында сез ачу тота дип курыккансыз! Боерыкка буйсынмаган кешеләргә генә җәза бирәм мин, сезнең кебек... кушканны артыгы белән тырышып үтәүчеләрне җәзаламыйм... Моның дәлиле шул — мин сезне чакырткан көнне исегезгә төшерегез дә шул көнне кич булган вакыйганы хәтерләгез.

Нәкъ шул кичне Бонасье ханымны урлаганнар иде.

Д'Артаньян калтыранып куйды; моннан ярты сәгать кенә элек үзе яныннан каретада җилдереп узып киткән бичара

хатынны исенә төшерде. Һичшиксез, Бонасье ханымны югалып торырга мәҗбүр иткән көч бу юлы да аны каядыр ашыгырга мәҗбүр иткән иде.

— Менә шулай,— диде кардинал,— бу араларда сезнең хакта берни ишетмәгәнлектән, сезнең ниләр эшләвегезне беләсем килгән иде. Хәер, сез миңа беркадәр рәхмәт тә әйтергә тиешсез: үзегез дә сизгәнсездер — сезне һәркайда кызгана килделәр.

Д'Артаньян ихтирам белән баш иде.

— Моның сәбәбе, әлбәттә, табигый гаделлек тойгысы гына түгел,— дип дәвам итте кардинал,— шулай ук мин сезгә карата үземчә беркадәр план да төзегән идем.

Д'Артаньянның гаҗәпләнүе арта барды.

— Мин бу планымны сезгә беренче тапкыр чакырган көнне сөйләп бирмәкче идем дә, сез килмәдегез. Бәхеткә каршы, алай соңгаруның комачаулыгы булмады, сез аны бүген ишетерсез. Менә бирегә, каршыма утырыгыз, д'Артаньян әфәнде! Сез асыл зат дворян, мине аяк өсте тыңлап тормагыз.

Шулай дип, кардинал егеткә утырырга урын күрсәтте. Ләкин д'Артаньян әлеге сөйләшүдән шулкадәр аптырап-шаккатып калган иде — әңгәмәдәше аңа «утырыгыз» дип тагын бер тапкыр әйтергә мәҗбүр булды.

— Сез батыр кеше, д'Артаньян әфәнде, сез сак акыллы кеше, анысы тагын да мөһимрәк,— дип сүзендә дәвам итте кардинал.— Акыллы һәм йөрәкле кешеләрне яратам мин. Курыкмагыз,— диде аннары елмаеп,— йөрәкле дигәндә мин батыр кешеләрне күз алдында тотам. Әмма сезнен әле яшь булуыгызга, тормышка яңа гына аяк баскан булуыгызга карамастан, бик көчле дошманнарыгыз бар, сак булмасагыз, алар сезне һәлак итүе ихтимал!

— Әйе шул, галиҗәнап,— диде егет,— кызганычка каршы, аларга андый эш эшләве бик ансат, чөнки аларның бик көчле, бик куәтле ярдәмчеләре дә бар, ә мин — япа-ялгызым!

— Анысы шулай, әмма сез япа-ялгыз булсагыз да бик күп эш башкаргансыз инде һәм тагын да күбрәк башкарырсыз әле — анысына мин шикләнмим. Ләкин, минемчә, билгесезлекләр белән тулган юлыгызда сезгә бер әр җитәкче кирәк, чөнки сез, ялгышмасам, Парижга, карьера ясап, дан-шөһрәткә ирешү нияте белән килгән идегез.

— Минем яшьтә әле, галиҗәнап, чынга ашмас хыялый өметләр белән генә яшиләр.— диде д'Артаньян.

— Чынга ашмас хыялый өметләр белән акылсыз кешеләр генә яши, әфәндем, ә сез акыллы кеше. Карагыз әле, минем гвардиямдә лейтенант дәрәҗәсе алу һәм кампаниядән соң рота командиры булу турында ни диярсез икән сез?

— О, галиҗәнап!

— Сез риза, шулаймы?

— Галиҗәнап...— диде д'Артаньян уңайсызланып.

— Ничек, баш тартасызмы? — диде кардинал гаҗәпләнеп.

— Галиҗәнап, мин король хәзрәтләре гвардиясендә хезмәт итәм бит, ул хезмәтемнән риза булмаслык бернинди сәбәбем юк.

— Ләкин, минем уемча, минем гвардиячеләрем бер үк вакытта король хәзрәтләре гвардиячеләре булып та санала, шулай булгач, сез француз армиясенең кайсы частенда хезмәт итсәгез дә, корольгә хезмәт итәсез,— диде кардинал бу сүзгә каршы.

— Галиҗәнап, сез минем сүземне дөрес аңламадыгыз.

— Сезгә сылтау кирәк, шулаймы? Аңлыйм! Ярый алайса! Сезнең андый сылтавыгыз бар. Зуррак дәрәҗәгә күтәрелү, башланасы кампания, мин сезгә тәкъдим итә торган форсат — болары бөтен кеше өчен дә, сезнең өчен исә бигрәк тә ышанычлы химаяче булдыру кирәк, чөнки сезгә, д'Артаньян әфәнде, шуны белеп тору да зарар итмәс: миңа сезнең өстән җитди шикаятьләр килде; сез бөтен көннәрегез вә төннәрегезне дә корольгә хезмәткә генә багышлап бетермисез икән.

Д'Артаньян кызарынып китте.

— Менә монда,— диде кардинал, кулын кәгазь өеме өстенә куеп,— миндә сезгә кагылышлы бөтен бер дело ята, ләкин, аны укып чыгудан элек, минем сезне күреп сөйләшәсем килде. Мин сезнең бик тәвәккәл кеше икәнегезне беләм, сезнең хезмәтегез, тиешле юнәлеш биреп барганда, зыян урынына зур файда китерер иде. Менә шул, уйлагыз да хәл кылыгыз.

— Сезнең мондый мәрхәмәтегезне күреп, мин бик уңайсыз хәлдә калдым, галиҗәнап,— диде д'Артаньян,— сез хәзрәтләрнең олы җаны каршында мин үземне мәхлук бер җан иясе дип кенә хис кылам, тик әгәр дә сез, галиҗәнап, миңа ихлас күңелдән әйтергә рөхсәт итсәгез...

Шулай дигәч, д'Артаньян сүзеннән туктап калды.

— Әйтегез.

— Яхшы! Алайса сез галиҗәнап хәзрәтләренә мин менә нәрсә әйтәм: минем барлык дусларым мушкетерлар белән король гвардиячеләре арасында, ә дошманнарым, аңлашылмый торган ниндидер сәбәпләр аркасында, сез галиҗәнап хәзрәтләренә хезмәт итә, шуңа күрә, галиҗәнап, мин сезнең тәкъдимегезгә риза булып күнсәм, мине монда ачык чырай белән каршы алмаслар иде, тегендә дә миңа ачык төс белән карамаслар иде.

— Сез, үзегез турындагы фикерегез артык зураеп китеп, мине сезгә чынлыктагы бәһагездән кимрәк тәкъдим итә дип уйламыйсызмы? — дип сорады кардинал беркадәр мыскылчан көлемсерәп.

— Галиҗәнап, сез миңа карата тиешле булганыннан йөз өлеш мәрхәмәтлерәксез, һәм, киресенчә, мин үземне әле сезнең рәхим-шәфкатегезгә лаек булырлык эш күрсәткәнем юк дип саныймын. Озакламый, галиҗәнап, Ларошельне камау башланачак. Мин сез галиҗәнап хәзрәтләренең күз алдында хезмәт

итәчәкмен, әгәр дә шул камауда мин сезнең илтифатыгызга лаек булырлык эшләр кыла алсам, ул чагында, ул чагында инде, һич югы, сезнең химаячелегегезне аклардай берәр төрле батырлык күрсәткән булачакмын,— әлбәттә, сез миңа андый химаячелекне кирәк дип тапсагыз. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар, галиҗәнап. Бәлки, киләчәктә мин үземне үзем аямыйча сезгә хезмәт итү хокукына да ирешермен, хәзер исә алай итү сезгә сатылу сыман бер нәрсә булып тоелыр иде.

— Икенче төрле итеп әйткәндә, сез миңа хезмәт итүдән баш тартасыз, әфәндем,— диде кардинал ачуы килгән бер төс белән, ләкин шул ук вакытта чыраеннан егетне ихтирам итү сыман бер нәрсә дә сизелеп тора иде.— Яхшы алайса, ирекле булып калыгыз, яратуыгызны да, яратмавыгызны да эчегездә саклый бирегез.

— Галиҗәнап...

— Җитте, җитте,— диде кардинал,— мин сезгә ачу тотмыйм, әмма үзегез дә аңлыйсыздыр: әгәр без дусларыбызны яклыйбыз һәм аларга яхшылык итәбез икән, дошманнарыбызга берни белән дә бурычлы түгелбез. Тик шулай да мин сезгә бер киңәш бирәм: сак булыгыз, д'Артаньян әфәнде, чөнки минем химаячелегемнән мәхрүм булган минуттан башлап сезнең җаныгыз сукыр бер тиен дә тормаячак.

— Сак булырга тырышырмын, галиҗәнап,— диде д'Артаньян батыр бер ышаныч белән.

— Соңрак берәр төрле бәхетсезлеккә тарсагыз, минем сезне үзем чакыртып китергәнемне һәм андый бәхетсезлекне булдырмас өчен хәлемнән килгәннең бөтенесен эшләргә тырышканымны исегезгә төшерерсез,— диде Ришелье бик мәгънәле итеп.

Д'Артаньян, кулын күкрәгенә куеп һәм баш иеп:

— Галиҗәнап хәзрәтләре, киләчәктә ниләр генә булмасын, шушы минутта минем өчен кылган яхшылыкларыгыз өчен мин гомерем буе сезгә рәхмәт укыячакмын,— дип җавап кайтарды.

— Шулай итеп, д'Артаньян әфәнде, үзегез әйткәнчә, без кампаниядән соң күрешербез әле. Мин сезне күзәтеп торырмын, чөнки мин үзем дә анда булам,— диде кардинал, ишарәләп кенә д'Артаньянга үзе киячәк искиткеч шәп гаскәри киемнәрен күрсәтте.— Аннан әйләнеп кайткач инде... аннан кайткач, исәп-хисапны өзәрбез!

— О, галиҗәнап! — дип кычкыра төшеп эндәште д'Артаньян.— Ачу-каһәрегездән берүк йола күрегез мине. Әгәр минем үземне намуслы кеше кебек тотуыма ышансагыз, берүк гадел була күрегез, галиҗәнап.

— Егетем, әгәр бүген әйткәннәремне сезгә тагын бер тапкыр әйтергә мөмкинлек туса, мин ул сүзләрне әйтергә вәгъдә итәм,— диде Ришелье.

Кардиналның бу соңгы сүзе аның бик яман икеләнүен-шикләнүен белдерә иде; бу сүз д'Артаньянның йөрәгенә, туп-туры

янаудан бигрәк, курку салды, чөнки бу — кисәтеп кую дигән сүз иде. Шулай итеп, кардинал аны көтә торган ниндидер бәхетсезлектән саклап калырга теләде. Егет сүзен әйтмәкче булып авызын ачкан иде дә, кардиналның тәкәббер генә бер төс белән кулын изәве аудиенциянең тәмам икәнлеген аңлатты.

Д'Артаньян чыгып китте, әмма ишек төбенә чыгуга, аның үз-үзенә ышанычын бетереп, йөрәген курку баскан кебек булды; бу хәл тагын аз гына дәвам итсә дә, ул кардинал янына кире кереп китәсе иде. Әмма шул вакытны күз алдына җитди, кырыс чырайлы Атос килеп басты: әгәр д'Артаньян кардинал белән союзга риза булып чыкса, Атос аңа кул да бирмәячәк, Атос аннан ваз кичәчәк иде.

Әнә шуннан куркуы гына егетне бу адымыннан тыеп калды — чын мәгънәсендә асыл характерның үз тирәсендәгеләргә йогынтысы әнә шулай көчле була шул.

Д'Артаньян монда менгәндәге баскычтан кире төште; ишек төбендә үзен көтеп борчыла башлаган Атос белән дүрт мушкетерны күрде.

Д'Артаньян аларны тизрәк тынычландырырга тырышты, кардинал сараеннан хуҗа әфәндесе исән-сау әйләнеп чыккач, Планше калган постларга сакта торасы юк инде дип әйтергә йөгерде.

Дуслар Атос квартирына кайткач, Арамис белән Портос бу сәер күрешүнең сәбәпләрен сорашырга керештеләр, ләкин д'Артаньян аларга Ришельеның егеткә лейтенант дәрәҗәсендә үз гвардиясенә хезмәткә керергә тәкъдим итүен һәм ул тәкъдимнән үзенең баш тартканлыгын гына әйтте.

— Бик дөрес эшләгәнсез! — диделәр Портос белән Арамис бертавыштан.

Атос, уйга калып, берни эндәшмәде. Ләкин, икәү генә калгач, дустына әйтте:

— Сез ничек эшләргә тиеш булсагыз, шулай эшләгәнсез, д'Артаньян, тик шулай да ялгышлык эшләгәнсездер, бәлки,— диде.

Д'Артаньян көрсенеп куйды, чөнки бу тавыш аңа алдагы көндә үзен зур бәхетсезлекләр көтүен әйтеп торган эчке бер тавышка бик аваздаш иде.

Иртәгесе көн походка хәзерләнү мәшәкатьләре белән узды; д'Артаньян де Тревиль әфәнде белән саубуллашып кайтты. Ул чагында әле бөтенесе дә гвардиячеләр белән мушкетерларның аерылышулары озакка булмас дип уйлый, чөнки ул көнне король парламент утырышында утыра, икенче көнне үк иртән юлга чыгарга җыенып тора иде. Шуңа күрә де Тревиль әфәнде д'Артаньяннан: «Берәр төрле ярдәмем кирәкмиме?» — дип кенә сорады, д'Артаньян исә горур гына бер төс белән: «Бөтен кирәк нәрсәм дә бар»,— дип җавап кайтарды.

Дезэссарның гвардия ротасы солдатлары төнлә де Тревиль әфәнденең мушкетерлар ротасы солдатлары белән очрашты-

лар — алар үзара дуслашып өлгергәннәр иде инде. Ходай күрешергә язган булса, бер күрешербез әле дип аерылышулары иде аларның. Шуңа күрә, табигый, төнне бик күңелле, шаушулы итеп уздырдылар, чөнки мондый чактагы зур борчуны зур гамьсезлек белән генә онытып торырга мөмкин иде.

Икенче көнне инде иртән, быргы тавышлары ишетелә башлау белән, дуслар хушлашып аерылыштылар; мушкетерлар де Тревиль әфәнде казармаларына, гвардиячеләр исә Дезэссар әфәнде казармаларына йөгерделәр, һәм ике капитан шундук үз роталарын король гаскәрләргә смотр ясыйсы төшкә — Луврга алып киттеләр.

Корольнең чырае бик күңелсез, хасталаган сыман күренә, шушы хәл аның кыяфәтендәге тәкәбберлекне беркадәр кимет төшкән кебек иде. Чыннан да, алдагы көнне, парламент утырышы вакытында, аның бизгәк өянәге кузгалды. Әмма ул шул ук кичне юлга кузгалырга дигән карарын үзгәртмәде һәм, моны кичектерергә кирәк дип үзен никадәр үгетләп карасалар да, король үзенең гаскәрләренә смотр ясарга теләвен белдерде, авыруын ихтыяр көче белән җиңәргә өметләнде.

Смотрдан соң гвардиячеләр походка үзләре генә чыгып киттеләр, мушкетерлар исә юлга король белән бергә кузгалырга тиешләр иде. Шушы хәлдән файдаланып, Портос бер дигән кием, кораллары, искиткеч шәп аты белән Аю урамыннан әйләнеп кайтырга ниятләде.

Прокурор хатыны аны өр-яңа мундирдан, бик шәп аты белән тәрәзә турысыннан узган чагында күреп алды. Ул Портосны бик каты ярата, хушлашмыйча-саубуллашмыйча җибәрәчәк түгел иде; ханым ымлап кына аңа атыннан төшеп, үзе янына керергә кушты. Портосның килеш-килбәте искиткеч, сокландыргыч иде; аягындагы шпорлары чак-чок килә, өстендәге көбәсе елкылдап тора, кылычы шалт та шолт ботларына бәрелә иде. Бу юлы инде аны мондый дәһшәтле кыяфәттә күргәч, писерләр дә авыз ермадылар.

Мушкетерны Кокнар әфәнде кабинетына алып керделәр. Өр-яңадан киенеп-коралланып алган тудыкасын күргәч, прокурорның кечкенә генә соры күзләре зәһәр ачудан очкынланып ялтырап китте. Хәер, Кокнар әфәнденең ачуын йомшатырлык беркадәр юанычы да бар иде: бу походны бик куркыныч, хәтәр булачак дип сөйлиләр, шуңа күрә прокурор Портосны шунда, шәт, үлеп тә калыр дип өметләнә иде.

Портос якты чырай белән метр Кокнарның хәл-әхвәлен сорашты да аның белән саубуллашып, кабинеттан чыгып китте, метр Кокнар исә егеткә уңышлар теләп калды. Кокнар ханымга килгәндә инде, ул, әлбәттә, күз яшьләрен тыеп кала алмады, мәгәр аның бу кадәр өзгәләнүен гаеп итмәделәр, чөнки ханымның туган-тумачалары өчен үлеп торганлыгын бик яхшы беләләр, шулар аркасында ире белән аның арасында каты гына низаглар да чыккалап тора иде.

Әмма чыплап торып саубуллашу Кокнар ханымның йокы булмасендә булды һәм ул чын мәгънәсендә үзәк өзгеч булды.

Прокурор хатыны, тәрәзәдән сикереп төшәргә җыенгандай сузылып, яулык болгый-болгый, сөйгән егетен күздән югалганчы озатып калды. Портос бу мәхәббәт галәмәтләрен мондый тамашага күнегеп беткән бер кеше шикелле генә кабул итте, урам чатыннан борылып киткән чагында гына бер мәртәбә эшләпәсен күтәрде дә саубуллашып селеккәләп алды. Арамиска килгәндә исә, ул озын итеп бер хат язды. Кемгә атап язганын беркем белмәде. Бу кичне үк Турга китәргә тиешле Кәтти күршe бүлмәдә Арамисның эше беткәнен көтеп утыра иде.

Атос йотымлап-йотымлап кына соңгы шешә испан шәрабын эчеп бетереп килә иде.

Бу вакытта инде д'Артаньян үзенең ротасы белән бергә походка чыгып киткән иде.

Сент-Антуан бистәсенә җиткәч, ул, борылып, кәефле генә бер төс белән Бастилиягә күз салды. Карашын Бастилиягә таба гына төбәгәнлектән, ул кола атка атланган милединың шикле кыяфәтле ниндидер ике кешегә бармагы белән төртеп егетне күрсәтүен шәйләмәде; әлеге ике кеше әйбәтләбрәк күрү өчен гвардиячеләр янына якынрак килделәр дә «Шушымы?» дигән сыман миледига карадылар, хатын ымлап кына «нәкъ үзе» дигәнне аңлатты һәм, кушканын үтәгән чакта ялгышлык булмаячагына ышангач, атын шпорлап китеп тә барды.

Таныш булмаган әлеге ике кеше ротага ияреп бардылар да Сент-Антуан заставасы янында ливрейсыз бер хезмәтче тотып торган иярле атларга атландылар.

## *XI*

## *ЛАРОШЕЛЬНЕ КАМАП ТОРГАНДА*

Ларошельне камап алу Людовик XIII патшалык иткән чакта зур бер сәяси вакыйга һәм кардиналның зур бер хәрби эше була. Шуңа күрә ул хакта берничә сүз әйтеп китү кызыклы һәм кирәкле булыр; өстәвенә, бу камауның кайбер вакыйгалары без сөйлисе хәлләр белән бик тыгыз үрелгәнлектән, ул турыда әйтми китү мөмкин дә түгел.

Кардинал Ларошельне камаудан шактый зур сәяси максатлар күздә тота. Башта без шуларны тасвирлап китик, аннары инде кардинал хәзрәтләренә сәяси максатлар шикелле үк көчле тәэсир ясаган булырга тиешле хосусыйрак максатларга күчәрбез.

Һенрих IV тарафыннан, ныгытылган пунктлар сыйфатында, һугенотларга бирелгән зур калалардан хәзер алар кулында нибары Ларошель генә калган иде. Димәк, кальвинизмның бу соңгы терәген, халык чуалышлары һәм тышкы сугышлар тудыра торган бу җирлекне бетерергә, юк итәргә кирәк иде.

Моңа риза булмаган испаннар, инглизләр, итальяннар, төрле милләт авантюристлары, сугыш хезмәтеннән кайтып, төрле сектада торучы хәрбиләр, беренче чакыру булу белән үк, протестантлар байрагы астына җыелып, зур бер берләшмә хасил иттеләр, бу берләшмәнең тармаклары исә тиз генә үсеп, бөтен Европага таралды.

Шулай итеп, кальвинистлар кулындагы башка калалар җиңелгәннән соң аеруча бер әһәмият тоткан Ларошель ызгыш-талашчылар һәм дан-шөһрәткә омтылучылар оясына әверелде. Ул гына да түгел, Ларошель порты Франция дәүләтенә керер өчен инглизләргә юл ача торган соңгы порт иде, кардинал, Францияның күптәнге дошманы булган Англия өчен бу юлны ябып, Жанна д'Арк һәм герцог де Гиз эшләрен төгәлли иде.

Шуңа күрә берүк вакытта католик та, протестант та булган, иманы белән протестант, изге Рух ордены командоры буларак католик Бассомпьер, тумышы белән немец, җаны-рухы белән француз Бассомпьер, кыскасы, Ларошельне камаган чакта аерым бер отряд командиры булган бу Бассомпьер, үзе кебек үк протестант дворяннарның башларына аткан чагында әйткән:

— Менә күрерсез, әфәнделәр, без Ларошельне яулап алып бик зур ахмаклык эшлибез,— дигән.

Бассомпьер чыннан да хаклы булып чыга: Ре атавын тупка тоту аңа Севен драгонадалары * буласын белгертә, Ларошельне яулап алу исә Нант эдиктын ** бетерүгә хәзерлек була.

Елъязмачы, әйткәнебезчә, бөтенесен тигезләргә, бөтенесен гадиләштерергә омтылган министрның тарихка кереп калган шушы планнары белән бергә, гашыйк һәм көнче бер ирнең ваграк омтылышлары булганлыгын да танырга мәҗбүр.

Һәркемгә мәгълүм булганча, Ришелье королевага гыйшык тоткан; бу мәхәббәт аның өчен гади бер политик исәп кенә яисә тирән бер тойгы булгандырмы (Анна Австрияле үз тирәсендәге ирләрнең йөрәгендә андый тойгы тудыра торган булган),— без ул кадәресен белмибез, тик, ничек кенә булмасын, без бу хикәябезнең сөйләп узган вакыйгаларында шуны күрдек: Бекингэм кардиналдан өстен чыкты һәм икеме-өчме очракта, бигрәк тә теге асылташлар белән булган вакыйгада, өч мушкетерның тугрылыгы һәм д'Артаньянның батырлыгы аркасында, кардиналны бик каты көлкегә дә калдырды.

Шулай итеп, Ришельеның максаты Францияне дошманнан арындыру гына түгел, көндәшеннән үч алу да була; өстәвенә, мондый көрәштә кылыч белән генә түгел, бәлки бөтен бер

---

* Людовик XIV заманында һугенотларга каршы оештырылган драгуннар экспедициясе.

** Нант эдикты (1598 ел) һугенотларга дин иреге биргән; 1685 елда бетерелгән.

король дәүләтенең хәрби көче белән коралланган кешесенә бәрабәр рәвештә бу үч шактый каты һәм тәэсирле булырга тиеш дип уйланыла.

Англияне җиңү — Бекингэмны җиңү, Англиядән өстен чыгу — Бекингэмнан өстен чыгу икәнен һәм, ниһаять, Англияне Европа алдында хурлыкка калдыру — Бекингэмны королева каршында хур итү икәнен кардинал бик яхшы белә.

Үз нәүбәтендә Бекингэм да, Англиянең абруен беренче урынга куюына карамастан, шул ук кардинал кичергән теләк-омтылышлардан чыгып эш итә; ул да үзенең шәхси үчен кайтарырга омтыла,— Бекингэм бернинди йомыш сылтавы белән дә Франциягә илче сыйфатында гына килә алмый, ул анда җиңүче буларак килеп керергә тели.

Моннан инде ике гашыйк ирнең теләге белән көчле ике дәүләтне сугышыр дәрәҗәгә җиткергән бу уенның төп максаты Анна Австрияленең бер ягымлы күз карашы икәнлеге үзеннән-үзе аңлашылса кирәк.

Беренче җиңү герцог Бекингэм ягында була: ул туксан кораб һәм егерме меңләп солдат белән искәрмәстән генә Ре атавына килә дә шунда король исеменнән командалык итүче граф де Туаракка кинәт һөҗүм ясап, каты сугыштан соң гаскәрен атауга төшерә.

Җәяләр эчендә генә әйтеп китик: шушы сугышта барон де Шанталь һәлак була; аның яшь ярымлык ятим бер кызы кала.

Соңыннан әнә шул кыз үсеп җитеп де Севинье ханым була.

Граф де Туарак гарнизоны белән Сен-Мартен крепостена чигенә, Ла Пре дип аталган кечкенә генә фортта йөзләп кешесен калдыра.

Бу хәл инде кардиналны ашыгырга мәҗбүр итә һәм Ларошельне камау эшенә (бу мәсьәлә инде тәмам хәл ителгән санала) җитәкчелек итү өчен король белән үзе шунда барганчы ук, башлангыч операцияләргә җитәкчелек итү өчен ул алдан герцог Орлеанлыны җибәрә һәм сугыш хәрәкәтләре башланасы төшкә аның карамагындагы бөтен гаскәрләрне китерергә куша.

Дустыбыз д'Артаньян да әнә шул алдынгы отрядта бара иде.

Әйткәнебезчә, король парламент утырышы бетү белән үк анда китәргә уйлап тора иде, ләкин шул утырыштан соң, 23 нче июнь көнне ул бизгәк өянәге кузгала башлаганын тойды; шулай да барырга карар итте, әмма юлда барганда хәле начарланып китеп, ул Виллеруада туктап калырга мәҗбүр булды.

Король кая туктаса, мушкетерлар да шунда туктады, шул сәбәпле бары тик гвардиядә генә хезмәт иткән д'Артаньян вакытлыча булса да үзенең якын дуслары Атос, Портос һәм Арамистан аерылган булып чыкты; әлбәттә, егет үз тирәсендә яше-

рен хәвеф-хәтәр барлыгын сизенгән булса, аңа күңелсез бер хәл булып кына тоелган бу аерылышу чынлап торып борчылырлык бер нәрсәгә әйләнгән булыр иде.

Шуңа да карамастан, ул 1627 елның 10 сентябрендә, исәнсау килеш, Ларошель янындагы лагерьга килеп җитте.

Монда хәлләр үзгәрмәгән иде: Ре атавының хуҗалары — герцог Бекингэм белән аның инглизләре — бигүк уңышлы булмаса да, Сен-Мартен крепосте белән Ла Пре фортын камарга тырышуларында дәвам итәләр; Ларошельгә каршы сугыш хәрәкәтләре моннан ике-өч көн элек кенә башланган, кала янына әле яңарак кына герцог Ангулемле кордырган яңа форт моңа төп сәбәп булган иде.

Дезэссар командалыгындагы гвардиячеләр францисканнар монастырена урнаштылар.

Белгәнебезчә, д'Артаньян мушкетер булырга хыялланганлыктан, бу иптәшләре арасында аның якын дуслары бик аз иде, шуңа күрә ул, үз уйларына чумып, ялгызы йөрергә мәҗбүр иде.

Егетнең уйлары исә бигүк күңелле түгел иде: Парижга килгәннән соң узган ике ел гомер эчендә ул инде, үз теләгеннән тыш, бернигә тапкыр политик интригаларга катнашып китте, мәхәббәт һәм карьера өлкәсендәге шәхси эшләре исә әллә ни алга тәгәрәмәде.

Мәхәббәт мәсьәләсенә килгәндә, ул яраткан бердәнбер хатын Бонасье ханым иде, әмма Бонасье ханым юкка чыкты, егет аңа ни булганын да белми иде.

Карьера мәсьәләсенә килгәндә исә, ул, бик бәләкәй бер кеше булуына карамастан, кардинал хәтле кардиналны, ягъни корольдән башлап, дәүләттәге иң зур затларны дер калтыратып торган бер кешене, үзенең дошманына әйләндерде.

Бу кеше аны сытып юкка чыгара алса да, ни өчендер әлегә алай итми иде; д'Артаньянның зирәк акылы өчен мондый мәрхәмәт матур киләчәккә күз сала торган якты өлгесе сыман бер нәрсә иде.

Моннан тыш, ул үзенә тагын бер дошман, тегесеннән куркынычсызрак дошман булдырды,— һич югы, егет үзе шулай дип уйлый,— әмма аны санга сукмау да ярамас — егетнең күңеле шулай сизә. Аның бу дошманы миледи иде.

Болар урынына д'Артаньян королеваның химаясенә һәм ягымлы карашына ирešте, ләкин ул заманда королеваның ягымлы карашы эзәрлекләнер өчен өстәмә бер сәбәп кенә була, аның химаячелеге исә, белгәнебезчә, бик начар сак: Шале белән Бонасье ханым моның ачык бер мисалы иде.

Шулай итеп, д'Артаньянның бу гомер эчендә ирешкән бердәнбер нәрсәсе бармагындагы биш-алты мең ливр бәһасендәге алмаз кашлы йөзек кенә иде; д'Артаньян бу алмазны королева күзенә күренү, үзен таныту өчен берәр вакыт кирәк булып куюы бар дип сакларга тырышса да, аны сата алмагач, хәзер-

гә ул асылташның да бәясе аның аяк астындагы ташлар бәһасе шикелле генә иде.

Без «аның аяк астындагы ташлар» дидек, чөнки д'Артаньян, шулар турында уйлана-уйлана, ялгызы гына лагерь белән Ангутен авылы арасындагы матур-ямьле бер сукмактан атлап бара иде; шулай уйланып атлый торгач, ул бераз ераграк та киткән булып чыкты; көн инде кичкә авышып килә иде, кинәт шунда, баеп барган кояш яктысында, егеткә койма артыннан мушкет көпшәсе ялтырап киткән кебек тоелды.

Д'Артаньян үткен күзле, зирәк акыллы бер егет иде; мушкетның монда тиктомалга килмәгәнлеген, аны кулына тоткан кешенең дә койма артында дусларча ният белән посып тормаганлыгын ул шундук абайлап алды. Шулай итеп, тиз генә моннан таярга җыенганда гына юлның икенче ягында, зур бер таш артыннан икенче мушкет көпшәсе күренде.

Мөгаен, егетне үтерергә дип сагалап торалар иде.

Д'Артаньян ялт кына беренче мушкетка күз салды һәм көпшәсе үзенә таба төбәлә башлаганны күреп, йөрәге дерт итеп куйды; мушкет көпшәсе төбәлеп туктауга, д'Артаньян шундук җиргә йөзтүбән капланды. Нәкъ шул минутта гөрс итеп мушкет шартлады һәм егет баш өстеннән генә сызгырып пуля узганын ишетте.

Тизрәк ашыгырга кирәк иде; д'Артаньян ялт кына сикереп торды һәм нәкъ шул минутта икенче мушкет пулясы әле яңа гына егет йөзтүбән яткан төштәге ташларны туздырып китте.

Д'Артаньян «чигенмәде» дип әйтсеннәр өчен генә мәгънәсезгә үлемгә барып керә торган акылсыз батырлардан түгел иде; өстәвенә биредә батырлык хакында сөйләү урынсыз да: д'Артаньян тозакка килеп капкан иде бит.

«Өченче тапкыр атсалар, беттем!» — дип уйлады егет.

Һәм шундук якташларына хас бер җитезлек белән лагерьга таба элдертте; тик, никадәр каты чапса да, беренче мушкеттан аткан кеше мылтыгын яңадан корып өлгерде һәм егеткә икенче тапкыр атты, җитмәсә, шундый төз атты — пуля д'Артаньянның тула эшләпәсенә тиеп, эшләпәне бер ун адымга очыртып җибәрде.

Д'Артаньянның башка эшләпәсе юк иде; шуңа күрә ул, чаба биреп, эшләпәсен иелеп җирдән алды да, тыны-көне бетеп, агарынып, лагерьга кайтып җитте һәм аннары, утырып, беркемгә берни әйтмичә, уйланырга кереште.

Әлеге хәлнең өч сәбәбе булуы ихтимал иде.

Беренчесе һәм иң гадие: аны Ларошель кешеләре сагалап торган булуы мөмкин, корольнең гвардиячесен юк итүдән алар тайчанмаслар: беренчедән, берәү булса да дошманнары кими тора, икенчедән, бу дошманның кесәсендә бер янчык акчасы да булуы ихтимал.

Д'Артаньян эшләпәсен кулына алып, пуля тишкән тишекне карады да башын чайкап куйды. Бу пуля мушкетныкы түгел,

моны озын көпшәле мылтыктан атканнар, тегенең бик төз атуы егетне башта ук гади коралдан атмадылар дигән уйга китергән иде: пуля калибрлы түгел, шулай булгач, аны хәрбиләр сагалап тормаганнар.

Ана кардинал җәнапларының да шушы рәвешле илтифат күрсәтүе ихтимал бит. Укучы хәтерли торгандыр: д'Артаньян баеп барган кичке кояш яктысында мылтык көпшәсен күреп алган чагында нәкъ әнә шул кардинал хәзрәтләренең егеткә карата сабыр-түзем булуына гаҗәпләнеп уйланып бара иде.

Д'Артаньян тагын бер тапкыр башын чайкады. Кардинал хәзрәтләре бер бармагы белән дә юк итә алырлык кешеләр белән эш иткәндә андый чараны бик сирәк куллана иде шул.

Болай итеп милединың да үч алырга тырышуы ихтимал бит. Бусы инде дөреслеккә якынрак кебек иде.

Д'Артаньян үзен үтерергә маташучыларның йөзләрен төсмерләргә, киемнәрен күз алдына китерергә тырышса да — хәтерли алмады; бик каты чапты шул, юньләп карый да алмады.

— Кайда сез, кадерле дусларым? Менә хәзер сез бик кирәк идегез бит миңа! — дип пышылдап сөйләнеп куйды д'Артаньян.

Төнлә бик начар йоклады. Өчме-дүртме тапкыр сискәнеп йокысыннан уянды: янына кемдер килеп, хәнҗәр белән кадамакчы булган кебек тоелды. Ләкин ул-бу хәл булмады, төн тыныч кына үтеп китте.

Шулай да бүген булмый калганның иртәгә булуы бик ихтимал иде һәм д'Артаньян моны бик яхшы белеп тора иде.

Тышта көн ямьсез дигән сылтау белән ул көне буе өйдә утырды: үзенә үзе акланыр өчен генә кирәк булды аңа бу сылтау.

Әлеге хәл булганның өченче көнендә, иртәнге сәгать тугызда, җыелырга быргы уйната башладылар. Герцог Орлеанлы постларны карап йөри икән. Гвардиячеләр тиз генә мылтыкларын алып сафка тезелделәр, д'Артаньян да иптәшләре арасына барып басты.

Герцог җәнаплары, атына атланып, сафка тезелгән гаскәрләр алдыннан узды, аннары барлык өлкән офицерлар галиҗәнап янына килеп аны сәламләделәр, болар арасында гвардия капитаны Дезэссар да бар иде.

Беравыктан д'Артаньянга Дезэссар ымлап кына аны үзе янына чакыра кебек тоелды. Егет, ялгышмагаем дип, башлыгының тагын бер тапкыр ымлаганын көтте, капитан янә кулын изәгәч инде, д'Артаньян сафтан чыгып, аның янына барды.

— Хәзер герцог җәнаплары бик хәтәр бер эш башкару өчен иреклеләр эзләячәк. Шул эшне башкарып кайткан кешеләр зур хөрмәт казаначак. Мин сезне әзер булып торыгыз дип әйтергә чакырдым.

Гасконь егете, герцог алдында егетлек күрсәтергә җай чыгуына сөенеп:

— Рәхмәт, капитан әфәнде! — диде.

Камалудагы Ларошель кешеләре төнлә, кача-поса килеп, моннан ике көн генә элек король армиясе алган бастионны кире кайтарганнар; бу бастионны хәзер ничек саклауларын белү өчен шунда бик хәтәр рекогносцировкага кешеләр җибәрмәкчеләр икән.

Чыннан да, берничә минуттан соң герцог Орлеанлы:

— Миңа ышанычлы бер кеше җитәкчелегендә үзләре теләп баручы өч-дүрт кеше кирәк,— дип кычкырды.

— Ышанычлы кешегә килгәндә, миндә андый кеше бар, галиҗәнап,— диде Дезэссар, д'Артаньянны күрсәтеп,— үзләре теләп баручыларга килгәндә исә, сез әйтегез генә — кешеләре табылыр.

— Минем белән бергә үлемгә барырга теләүче дүрт кеше булырмы монда? — дип кычкырды д'Артаньян, кылычын күтәреп.

Гвардияче ике иптәше шундук саф алдына чыгып бастылар, аларга тагын ике солдат килеп кушылды, шулай итеп дүрт кеше булды да; иң алдан чыгучыларны үпкәләтмәс өчен, д'Артаньян калганнардан берсен дә алмады.

Ларошель кешеләре бастионны алганнан соң аннан бөтенләй киткәннәрме, әллә анда гарнизон калдырганнармы — шул нәрсә билгеле түгел иде; моны белү өчен, шактый якын барып, әлеге урынны карап кайтырга кирәк иде.

Д'Артаньян дүрт юлдашы белән юлга кузгалып, траншея буйлап китте; ике гвардияче аның белән янәшә атлый, ә солдатлар арттан бара башладылар.

Траншеяның таш тышлыгына ышыкланып, алар шактый ара уздылар һәм бастионга йөз адым чамасы кала гына туктадылар. Шунда д'Артаньян, борылып карагач, теге ике солдатның юкка чыкканлыкларын абайлады.

Ул аларны куркып артта калганнардыр дип уйлады да алга таба баруында дәвам итте.

Траншея борылышына җиткәндә д'Артаньян белән ике гвардияче иптәше бастионнан алтмыш адым чамасында гына иделәр. Бастион эчендә кеше әсәре күренми, анда беркем дә юк кебек иде.

Өч егет әллә тагы да бара төшәргәме дип киңәшеп торган чакларында кинәт әлеге таш бастион тирәли төтен боҗрасы хасил булды һәм д'Артаньян белән юлдашлары яныннан дистәләгән пуля сызгырып узды.

Алар өчен нәкъ кирәк нәрсә билгеле булды: димәк, бастионны саклыйлар икән. Мондый куркыныч урында торып калу файдасыз бер саксызлык күрсәтү генә булыр иде; д'Артаньян белән гвардияче ике иптәше кирегә борылдылар да качкан шикелле чигенә башладылар.

Траншеяның дошман пулясыннан ышыкланырлык борылышына житкәндә гвардиячеләрнең берсе жиргә егылды; пуля аның күкрәгенә кергән иде. Исәне лагерьга таба чаба бирде.

Д'Артаньянның иптәшен ташлап калдырасы килмәде; ул аны, үзебезнекеләргә кайтарып житкерергә, кирәк дип, иелеп күтәрмәкче генә булган иде — нәкъ шул вакытны ике тапкыр мылтыктан аттылар: бер пуля яралы гвардиячене башына килеп тиде, икенчесе д'Артаньяннан ике дюйм гына читтәнрәк узып, ташка яньчелде.

Егет ялт кына борылып карады, траншея борылышы бу урынны бастионнан ышыклап торганлыктан, аннан аткан булулары мөмкин түгел иде. Ул, үзен ташлап киткән теге ике солдатны хәтерләп, өченче көн үзен үтерергә маташуларын исенә төшерде. Бу юлы инде моны тәгаен ачыкларга кирәк дигән карарга килде д'Артаньян һәм, үлгәнгә салышып, иптәшенең мәете өстенә капланды.

Моннан утыз адым чамасындагы ташландык жир ныгытма артыннан шундук ике баш күренде: болар теге артта калган ике солдатның башы иде. Д'Артаньян ялгышмаган: бу ике солдат бары тик аны үтерер өчен генә ияреп килгәннәр, егетнең үлеп калуын дошман эшенә сылтарга ниятләгәннәр иде.

Д'Артаньян бары тик яраланып кына калып, соңыннан аларның жинаятен фаш итмәсен өчен, әлеге ике солдат, егетнең эшен бетерик дип, якынрак килделәр; бәхеткә каршы, алар, д'Артаньянның хәйләсенә алданып, мылтыкларын яңадан кормаганнар иде.

Ара ун адым чамасы гына калгач, д'Артаньян (егылган чагында кылычын кулыннан ычкындырмаска тырышкан иде) ялт кына сикереп торды да бер омтылуда тегеләр янына барып та житте.

Бу ике бәндә, д'Артаньянны үтермичә лагерьга таба йөгерсәләр, үзләрен егет фаш итәчәген төшенделәр; шуңа күрә аларның беренче уйлары дошман ягына качу булды. Берсе мылтыгын көпшәсеннән тотты да гөрзи кебек селтәп жибәрде, д'Артаньян читкә тайпылып өлгермәсә, бетергәннәр дә булыр иде аны. Ләкин егет читкәрәк тайпылып калды, шуның белән бандитка качарга юл да ачты, һәм анысы бастионга таба чаба башлады. Бастионны саклаучы Ларошель кешеләре, бу бәндәнең үзләренә таба нинди ният белән йөгерүен белмичә, ут ачтылар, һәм әлеге хыянәтче, кулбашына пуля тиеп, жиргә егылды.

Ул арада д'Артаньян, кылычын тотып, икенче солдат өстенә ташланды; көрәш озакка сузылмады, бу бәндәнең корылмаган мылтыгыннан башка коралы юк иде; гвардияче егетнең кылычы ату куркынычы калмаган мылтыкның көпшәсе буйлап шуып төште дә тегенең ботына килеп кадалды, егетне үтерергә жыенган бәндә жиргә егылды. Д'Артаньян шундук кылыч очын аның бугазына китереп терәде.

— Ай, зинһар, үтермәгез! — дип кычкырып җибәрде бандит.— Берүк кызганыгыз, кызганыгыз, офицер әфәнде, бөтенесен сөйләп бирәм мин сезгә!

— Ул серләрең өчен генә сине кызганып тору кирәк микән? — диде егет, кылычын тери биреп.

— Үзегезнең яшисегез килсә, тыңлагыз! Сезгә бит әле нибары егерме ике генә яшь, сез чибәр, батыр, сез ни теләсәгез — шуңа ирешә аласыз.

— Сузма, сөйлә, әшәке җан, мине үтерергә кем кушты сиңа? — диде д'Артаньян.

— Бер хатын, мин аны белмим, миледи дип йөртәләр үзен.

— Ул хатынның үзен белмәгәч, исеме каян билгеле булды соң сиңа?

— Аның белән таныш иптәшем шулай диде. Ул хатын минем белән түгел, аның белән сөйләшкән. Иптәшемнең кесәсендә шул хатын язган хат та бар. Ишетүемә караганда, ул хатның сезнең өчен бик зур мәгънәсе булырга тиеш.

— Ә син үзең мондый явыз эшкә ничек катнашасы иттең?

— Иптәшем сезне үтерергә булыш әле диде дә, мин риза булдым.

— Мондый егетлегегез өчен теге хатын сезгә күпме акча түләде инде?

— Йөз луи.

— Оһо! — дип куйды егет көлеп.— Ул хатын минем җаным өчен бәяне зур куя, күрәсең. Йөз луи! Сезнең ише ике әшәке җан өчен бик зур байлык бит ул. Синең ни өчен риза булганыңны аңладым. Мин сине кызганып гафу итәм, тик бер шарт белән.

Солдат, әле бөтенләй үк өмет бетмәгәнлеген күреп, борчылган бер төс белән:

— Нинди шарт? — дип сорады.

— Син миңа иптәшеңнең кесәсендәге хатны алып килергә тиешсең.

— Бу бит барыбер мине үтерү дигән сүз! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды бандит.— Бастионнан ут яудырып торганда ничек алып килим мин ул хатны?

— Шулай булса да барып алып киләсең, яки, ант итеп әйтәм, минем кулдан үләсең.

— Зинһар, кызганыгыз! Шәфкать күрсәтегез, әфәндем! Үзегез сөйгән яшь ханым хакына! Сез аны дөньяда юк дип уйлыйсыздыр, мәгәр исән ул! — дип кычкырып сөйләнде бандит, канын югалту белән бергә хәле дә киткәнлектән, ул, тезләренә чүгеп, куллары белән җиргә таянды.

— Мин сөйгән бер яшь ханым барлыгын, аны дөньяда юк дип уйлавымны син каян беләсең? — дип сорады д'Артаньян.

— Иптәшем кесәсендәге хаттан.

— Менә, ул хатның минем кулда булырга тиешлеген үзең дә күреп торасың,— диде д'Артаньян.— Я, тизрәк бул, озакка

сузма, яки синең ише әшәке җанның канына кылычымны яңадан буйыйсым килмәсә дә, намуслы кеше буларак ант итеп әйтәм...

Д'Артаньян кулларын шундый хәтәр селтәп әйтте бу сүзләрен — яралы солдат урыныннан торырга мәҗбүр булды.

— Хәзер! Хәзер! — дип кычкырды ул куркуыннан батырая төшеп.— Барам... барам!...

Д'Артаньян солдатның кулыннан мылтыгын алды да, аны алга уздырып, кылыч очы белән иптәшенә таба этеп җибәрде.

Бу бичара адәмнең, артыннан канлы эз калдырып, үлем куркынычыннан агарынып, үзен... н егерме адым чамасындагы иптәшенең мәете янына саклана-саклана барырга маташуын карап торуы күңелгә бик авыр иде!..

Аның бөтен битенә шабыр салкын тир бәреп чыккан, куркудан чыраенда коты калмаган иде, д'Артаньян, моны күреп, кызганып куйды аны.

— Яхшы,— диде, солдатка җирәнеп карап.— Мин сиңа батыр кеше белән синең ише куркак кеше арасындагы аерманы күрсәтәм. Тукта. Үзем барам.

Д'Артаньян кызу-кызу атлап, як-ягына карана-карана, дошманның һәр хәрәкәтен күзәтеп, җиргә сыена-сыена икенче солдат янына барып җитте.

Максатка ике төрле юл белән ирешеп була иде: яралы солдатны шушында гына тентергә дә мөмкин яки, аның гәүдәсенә ышыкланып, аны күтәреп китәргә дә траншеяда тентергә була иде.

Д'Артаньян икенче юлны сайлады, үзен үтерергә ниятләгән солдатны дошман нәкъ ут ачкан чакта гына җилкәсенә күтәреп салды.

Җиңелчә генә этелеп куюы, өч тапкыр вышт-вышт итеп яралы солдатның тәненә пуля керүе, аның соңгы тапкыр кычкырып куюы һәм тартышып җан бирүе — болар барысы д'Артаньянга үзен үтерергә җыенган кешенең менә хәзер генә егетне үлемнән коткарып калуын белгертте.

Д'Артаньян траншеяга кайтып җитте дә мәетне үлек төсле агарынган яралы солдат янына ташлады.

Шундук аны тентергә дә кереште: күн бумажник, акча янчыгы,— монысында бандитның миледидан алган беркадәр акчасы бар иде ахры,— шакмак уйный торган стакан белән шакмаклар — үлгән солдаттан калган бөтен байлык шул иде.

Д'Артаньян стакан белән шакмакларны ташлаган төшендә калдырып, акча янчыгын яралы солдатка ыргытты да ашыгаашыга бумажникны ачты.

Кирәксез кәгазьләр арасыннан үзен үлем уты астына барырга мәҗбүр иткән теге хатны табып алды.

«Сез ул хатынны күздән яздырдыгыз, хәзер ул монастырьда тынычта яши. Сез аны берничек тә анда җибәрергә тиеш түгел идегез, һич югы, ир кешене ычкындырмаска тырышыгыз.

Минем кулым бик озын икәнлеге сезгә мәгълүм, әгәр анысын да ычкындырсагыз, миннән алган йөз луи акча хакын бик кыйммәт итеп түләвегез ихтимал»,— диелгән иде хатта.

Имзасы куелмаган булса да, хатның миледи кулы белән язылганлыгы күренеп тора иде — д'Артаньян моңа тамчы да шикләнмәде. Шуңа күрә ул аны бер дәлил булыр дип кесәсенә салды да, траншея чыгынтысына ышыкланып, яралы солдаттан сорау ала башлады. Солдат әле генә үлгән иптәше белән икәү бер яшь хатынны урларга алынган булганлыкларын әйтте. Бу хатын Лавильет заставасы аркылы Париждан чыгып китәргә тиеш булган, ләкин болар, кабакта утырып, ун гына минутка соңарганнар да каретаның үтеп киткәнен күрми калганнар икән.

— Сез ул хатынны нишләтмәкче идегез? — дип борчылып сорады д'Артаньян.

— Без аны Король мәйданындагы йортка китереп тапшырырга тиеш идек,— диде яраланган солдат.

— Әһә, әһә! Нәкъ шулай, милединың үзе янына,— дип пышылдап сөйләнде д'Артаньян.

Бу хатынның бик яман бер үч тойгысына бирелеп, егетне һәм аны яратучы кешеләрне юк итәргә тырышуын, король сараендагы хәлләрдән бик мәгълүматлы булып, барысын да белеп-күреп торуын аңлап, д'Артаньян калтыранып куйды. Үзенә кирәкле мәгълүматларны миледи кардиналдан ала иде, күрәсең.

Әмма шушы күңелсез-яман уйлар белән бергә, егетнең күңеленә кинәт хәйран калырлык бер уй килеп, аны сөендереп-рухландырып җибәрде: ул, ниһаять, бичара Бонасье ханым үзенең тугрылыгы өчен эләккән төрмәне королева эзләп тапканлыгын һәм аны шул төрмәдән азат иткән булуын төшенде. Хәзер инде егетнең Бонасье ханымнан хат алуы да, Шайо юлында төштәге шикелле елт итеп кенә күренеп китүе дә — барысы да аңлашылды егеткә.

Шулай итеп, шушы минуттан, Атос фараз кылганча, яшь ханымны эзләп табу мөмкинлеге туды, чөнки керү әмәле табылмаслык монастырь юк иде дөньяда.

Шуларны уйлагач, д'Артаньянның җаны бөтенләй тынычланып калды. Егет үзенең чыраендагы һәрбер үзгәрешне курка-курка гына күзәтеп торган яралы солдатка таба борылды да аңа кулын сузып:

— Әйдә, киттек, минем сине монда ташлап калдырасым килми. Миңа тотын да лагерьга кайтабыз,— диде.

— Кайтыйк,— диде яралы солдат, егетнең мондый олы җанлылыгына ышанып бетә алмады.— Тик сез мине дә дар агачына астырыр өчен алып кайтмыйсызмы соң?

— Мин инде сиңа бер тапкыр сүз бирдем, хәзер икенче тапкыр сине исән калдырырга сүз бирәм,— диде д'Артаньян.

Яралы солдат, җиргә тезләнеп, үзен коткарып калучы егет-

нең аякларын үбәргә кирәкте, ләкин д'Артаньянның дошманга якын гына төштә озак торырга исәбе юк иде, шуңа күрә ул әлеге солдатның рәхмәт белдереп маташуына шундук чик куйды.

Бастионнан ата башлауга ук лагерьга әйләнеп кайткан гвардияче егет дүрт юлдашын үлеп калдылар дип әйткән иде. Шуңа күрә полктагы бөтен кеше д'Артаньянның исән-сау кайтып килүен күреп гаҗәпләнделәр, моңа бик нык сөенештеләр.

Егет юлдашының ботындагы кылыч ярасын дошман эшенә сылтады. Икенче солдатның ничек үлеп калуын һәм үзләренең нинди куркыныч хәлләргә эләгүләрен сөйләп бирде.

Егетнең шушы сөйләгәннәре аңа чын триумф китерде. Бөтен гаскәр көн буе шушы экспедиция турында гына сөйләште, һәм герцог Орлеанлы үзе д'Артаньянга рәхмәтен тапшырырга кушты.

Һәр кылган яхшылык үзеңә дә яхшылык булып кайта, шуңа күрә д'Артаньянның кылган яхшылыгы егеткә югалган җан тынычлыгы булып кайтты. Чыннан да, д'Артаньян, бер дошманым үлеп калды, икенчесе миңа җаны-тәне белән бирелде, дип уйлады.

Мәгәр егетнең болай тынычлануы аның әле миледины белеп бетермәгәнлеген генә күрсәтә иде.

## XII

## АНЖУЙ ШӘРАБЫ

Корольнең өметсез диярлек авыруы турындагы хәбәрләрдән соң озакламый лагерьда ул сәламәтләнгән икән дигән имеш-мимешләр дә таралды. Ларошельне камауда король үзе дә катнашырга ашыкканлыктан, бөтен кеше: атка атланырлык хәлгә килү белән король юлга кузгалачак, дип сөйли башлады.

Бүген-иртәгә үзен армия башлыгы постыннан төшерәчәкләрен, шушы постны алыр өчен үзара ярышкан герцог Ангулемлы, яки Бассомпьер, я булмаса Шомберг белән алыштырачакларын белеп торган герцог Орлеанлы исә бу вакытта бернинди эш күрсәтми, дошманның көчләрен капшаштыргалаган булып бушка вакыт кына уздыра, инглизләрне Ре атавыннан куып җибәрердәй зур операция ясарга батырчылык итми иде. Ул атауда инглизләр әле һаман да Сен-Мартен крепосте белән Ла Пре фортын камалышта тоталар, французлар исә, үз тарафларыннан, Ларошельны камап алганнар иде.

Д'Артаньянга килгәндә, әйткәнебезчә, куркыныч бетеп, аны юкка санаган чактагы кебек, егет тынычлана төште; аның тик бер генә кайгысы бар — дусларыннан хат-хәбәр килми иде.

Ләкин ноябрь башларында беркөнне иртән Виллеруадан мондый бер хат алгач, бөтен мәсьәлә аңлашылган кебек булды:

«Д'Артаньян әфәнде!

Атос, Портос һәм Арамис әфәнделәр миндә мәҗлес ясап, бик шәп итеп күңел ачтылар, тик артык тавышланганлыктан, комендант, бик усал кеше, аларны берничә көнгә сак астына куйдырды. Шуңа да карамастан, мин аларның кушканын үтәп, сезгә үземнең унике шешә Анжуй шәрабын җибәрәм. Бу шәрабны алар бик яраттылар. Сездән үзләре исәнлегенә шул шәрабны эчүегезне үтенделәр.

Сезнең турылыклы вә ихтирамлы бер хезмәтчегез булып,
*Годо, мушкетер әфәнделәрнең трактирчысы».*

— Дусларымнан да хәбәр килер көн булыр икән! — дип сөенеп куйды д'Артаньян.— Димәк, бик ямансу чакларымда мин аларны искә алган кебек, алар да кәеф чиккән чакларында мине искә төшерәләр икән! Алар исәнлеге өчен эчәм, әлбәттә, рәхәтләнеп эчәм, тик ялгызым эчмим.

Шулай дигәч, д'Артаньян, Виллеруадан килгән бик шәп Анжуй шәрабын ялгызы гына эчмәс өчен, башкаларга караганда дусрак күргән ике гвардияче егетне чакырырга китте. Тик бу гвардиячеләрнең берсен инде кемдер бүгенге кичкә чакырган, икенчесен иртәгесе көнгә дәшкәннәр булып чыкты, шуңа күрә мәҗлесне берсекөнгә калдырырга туры килде.

Д'Артаньян, өйгә кайткач, унике шешә шәрабның бөтенесен дә гвардиянең поход буфетына илттерде, аларны бик әйбәтләп саклап тотарга кушты, ә бәйрәм көнне, сәгать уникегә мәҗлескә барысын да хәзерләп кую өчен, иртүк Планшены шунда җибәрде.

Планше үзенең метрдотель дигән мактаулы яңа исеменә горурланып, сер сынатасы килмәде, шуңа күрә мәҗлескә чакырылганнардан берәүнең Фурро исемле хезмәтчесе белән д'Артаньянны үтерергә җыенган теге ялган солдатны үзенә ярдәмгә алды. Бер частька да теркәлмәгән бу солдат, үзен д'Артаньян үлемнән йолып калганнан соң, егеткә, дөресрәге, Планшега хезмәтчелеккә күчкән иде.

Мәҗлес вакыты җиткәч, кунакларның икесе дә килеп урыннарына утырдылар. Табынга бик күп ашамлыклар тезеп куелды. Планше, беләгенә салфетка салган килеш, табын әзерләп йөри; Фурро шешәләрне ача, ә Бризмон — ярасы төзәлеп килгән солдатның исеме шулай иде — шешәдәге шәрабларны пыяла графиннарга бушата, чөнки шешә төпләренә, юлда селкенеп килү сәбәпле, күрәсең, ниндидер болганчык нәрсә утырган иде. Беренче шешәнең төбе беркадәр болганчыграк иде. Бризмон шешә төбендә калганнарын стаканга салды, яралы солдат әле бик хәлсез булганлыктан, д'Артаньян аңа шул шәрабны эчәргә рөхсәт итте.

Кунаклар аш ашап, беренче стаканны эчәргә дип күтәргәч кенә, Людовик форты белән Яңа форт ягыннан туп аткан тавышлар ишетелде: я камалудагылар, я инглизләр көтмәгәндә һөҗүм иткәннәр ахры дип уйлап, гвардиячеләр шундук кылычларын кулларына тоттылар; алар шикелле үк җитез д'Артаньян да кылычын кулына алды һәм шуннан өчесе дә үзләренең постларына йөгерделәр.

Эмма буфеттан атылып чыгу белән үк бу атышның сәбәбен дә төшенеп алдылар — бөтен кеше: «Яшәсен король! Яшәсен кардинал!» — дип кычкыра, бөтен җирдә дөбер-дөбер барабан кагалар иде.

Чыннан да, әйткәнебезчә, түземсезләнеп ашкынып торган король, ялсыз-нисез ике перегон узып, бөтен яраннары һәм ун мең солдатлы ярдәмче көче белән әле яңа гына бирегә килеп җиткән; аның алдыннан да, артыннан да мушкетерлар атлый иде.

Юл буена тезелгән рота сафында басып торган д'Артаньян кулларын болгый-болгый дуслары белән де Тревиль әфәндегә сәлам бирде. Дусларының да күзе д'Артаньяга төбәлгән иде, де Тревиль әфәнде дә аны шундук күреп алды.

Килеп җиту тантанасы бетү белән дуслар кочаклашып күрештеләр.

— Шайтан алгыры! Бик тә вакытлы килдегез бит әле! — диде д'Артаньян.— Ашлар суынып та өлгермәгәндер! Шулаймы, әфәнделәр? — диде егет, ике гвардиячегә мөрәҗәгать итеп, һәм шуннан соң аларны дуслары белән таныштырды.

— Оһо! Кәеф чигәбез икән! — диде Портос сөенеп.

— Безнең мәҗлестә хатын-кыз заты булмас дип беләм! — диде Арамис.

— Сезнең бу өнегездә адәм рәтле шәраб бармы соң? — дип сорады Атос.

— Ничек инде ул алай, шайтан алгырысы! Сез үзегез җибәргән шәраб бар бит миндә, дустым,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

Атос гаҗәпләнеп кайтарып сорады:

— Без җибәргән?

— Әйе, үзегез миңа җибәргән шәраб.

— Без сезгә шәраб җибәрдекмени?

— Оныттыгыз дамыни? Беләсезме, Анжуй виноградыннан эшләнгән йомшак кына шәраб!

— Әйе, нинди шәрабны күздә тотып әйткәнегезне аңлыйм.

— Сезнең иң яраткан шәрабыгыз.

— Әлбәттә, миндә шампань шәрабы да, шамбертен да булмаган чакта.

— Берни эшләп тә булмый шул инде! Шампань белән шамбертен булмагач, Анжуй шәрабы эчәргә туры килер.

— Димәк ки, сез Анжуй шәрабы китерттегез, тәмле тамак та соң үзегез, д'Артаньян! — диде Портос.

— Юк ла инде! Миңа сезнең исемнән җибәрелгән шәраб ул.

— Безнең исемнән? — диделәр өч мушкетер өчесе дә берьюлы.

— Арамис, әйтегез әле: ул шәрабны сез җибәрдегезме? — дип сорады Атос.

— Юк. Сезме, Портос?

— Юк. Сезме, Атос?

— Юк.

— Сез түгел икән, сезнең трактирчыгыз җибәргәндер, — диде д'Артаньян.

— Безнең трактирчы?

— Әйе! Сезнең трактирчы Годо, мушкетерлар трактирчысы.

— Һи, ул шәрабның каян килүендә безнең ни эшебез бар. Татып карыйк, әйбәт булса, эчәрбез, — диде Портос.

— Киресенчә, билгесез җирдән килгән шәрабны эчмибез, — диде Атос бу сүзгә каршы.

— Сүзегез хак, Атос, — диде д'Артаньян. — Димәк, сезнең берегез дә трактирчы Годога миңа шәраб җибәрергә кушмады?

— Юк! Ә ул сезгә безнең исемнән шәраб җибәргәнме?

— Менә хаты! — дип, д'Артаньян иптәшләренә теге хатны чыгарып бирде.

— Бу аның язуы түгел! — диде Атос. — Мин аның кулын таныйм, мин юлга кузгалыр алдыннан гына аңа бөтен компаниябез өчен акча түләдем.

— Ялган хат бу, безне берәү дә кулга алмады, — диде Портос.

— Д'Артаньян, безнең шулай ызгыш-талаш чыгаруыбызга ничек ышана алдыгыз? — диде Арамис шелтә белән.

Д'Артаньянның чырае агарынып китте, бөтен тәне калтыранып куйды.

— Төсеңә карарга куркыныч, ни булды сиңа? — диде Атос та, шундый бик сирәк очракта гына «син» дип эндәшә иде ул.

— Тизрәк йөгерик, дуслар! — дип кычкырып җибәрде д'Артаньян. — Бик яман шик килде күңелемә! Тагын теге хатынның шушылай үч алуы микәнни?

Хәзер инде Атосның да чырае агарынып китте.

Д'Артаньян буфетка йөгерде, өч мушкетер белән ике гвардияче дә аның артыннан чаптылар.

Ашханәгә килеп кергәч тә, д'Артаньянның беренче булып күзенә ташланган нәрсә идәндә газапланып тартышып яткан Бризмон булды.

Чырайлары көл төсле агарынган Планше белән Фурро тегеңә ничек тә ярдәм итмәкче булып маташалар, ләкин мондый ярдәмнең инде файдасыз икәнлеге күренеп тора: үлеп баручының йөзенә әҗәл газаплары чыккан иде.

— Ә, сез икәнсез! — дип кычкырды ул, д'Артаньянны күр-

гәч.— Сез мине исән калдырам дидегез, ә үзегез агу эчерттегез! Ай, бик яман кеше икәнсез!

— Минме?! Бахыр! Ни сөйлисең син! — диде д'Артаньян да кычкырып.

— Әйе, әйе, ул шәрабны миңа сез бирдегез, сез эчерттегез, сез миннән үч алырга уйлагансыз, бик яман кеше икәнсез.

— Ялгышасыз, Бризмон, ялгышасыз,— диде д'Артаньян.— Валлаһи... ант итеп әйтәм.

— Ходай бар ул! Ходай бер тотар әле сезне! Йа раббым, бу кеше дә менә минем кебек газапланып үлсен иде...

— Изге китап белән ант итеп әйтәм,— диде д'Артаньян, үлеп баручының янына ташланып,— мин ул шәрабның агулы икәнен белмәдем бит, үзем дә эчәргә җыенган идем.

— Мин ышанмыйм сезгә,— диде солдат. Һәм бик яман газапланып ята торгач, соңгы тапкыр сулышын алды да җан бирде.

— Коточкыч! Коточкыч! — дип пышылдап сөйләнде Атос. Портос исә шешәләрне ватарга кереште, Арамис, соңгарыбрак булса да, изге атаны чакырып килергә кушты.

— Ай, дусларым, сез мине тагын бер тапкыр үлемнән коткарып калдыгыз бит, мине генә түгел, менә бу әфәнделәрне дә коткардыгыз,— диде д'Артаньян. Шуннан соң гвардиячеләргә мөрәҗәгать итеп: — Әфәнделәр, күргәнегезне беркемгә дә сөйләмәвегезне үтенәм. Бу эшкә шактый зур кешеләр катнашкан булуы ихтимал, соныннан бөтен яманлыгы үзебезнең башка төшүе бар,— диде.

— Ай, әфәндем, ай, әфәндем, болай булгач, бәхет саклап калган бит мине! — дип сөйләнде коты ботына төшкән Планше.

— Ах, хөрәсән, син әле минем шәрабны эчәргә җыенган идеңме? — диде д'Артаньян, кычкыра төшеп.

— Король исәнлеге өчен дип, әфәндем, король исәнлеге өчен бик аз гына эчеп карамакчы идем дә, шул чакны Фурро мине чакыралар дип әйтте.

— Дөрес,— диде Фурро, куркуыннан тешләрен шык-шык китереп.— Үземә эчәргә комачауламасын дип, мин аны янымнан ераграк җибәрмәкче идем.

— Әфәнделәр,— диде д'Артаньян, гвардиячеләргә мөрәҗәгать итеп,— шушы хәлдән соң безнең сыйлануның нәтиҗәсе бик яман булып бетәчәген үзегез дә аңлыйсыздыр. Шуңа күрә мине гафу итүегезне үтенәм. Без аны икенче бер вакытка калдырып торыйк.

Ике гвардияче әдәпле генә итеп д'Артаньянны гафу итүләрен белгерттеләр дә, дүрт дусның үзләре генә калырга теләүләрен күреп, китеп бардылар.

Яннарында чит шаһитлар калмагач, гвардияче егет белән өч мушкетер, хәлнең бик җитди икәнлеген аңлыйбыз дигән бер төс белән, бер-берсенә карашып алдылар.

— Иң элек, әйдәгез бу бүлмәдән чыгып китик. Үз үлемё белән үлмәгән кешенең мәете янында тору хәерлегә булмас,— диде Атос.

— Планше, бу мескеннең мәетен сиңа тапшырам,— диде д'Артаньян.— Кадерләп күмсеннәр аны. Дөрес, җинаять кылган иде кылуын да, соңыннан тәүбә итте.

Шуннан соң, Бризмонны күмү мәшәкатен Планше белән Фуррога калдырып, дүрт дус бүлмәдән чыгып киттеләр.

Трактир хуҗасы аларга икенче бүлмә бирде, чиле-пешле күкәйләр белән Атос үзе коедан алган суны китереп куйды. Портос белән Арамиска кыскача гына итеп эшнең асылын сөйләп бирделәр.

— Күрәсезме, дустым, бернинди кызганусыз-аяусыз сугыш бу,— диде д'Артаньян Атоска.

Атос башын чайкап куйды.

— Әйе, әйе, күреп торам,— диде,— димәк, сез моны шул хатынның эше дип уйлыйсыз?

— Тәгаен, шуныкы.

— Ә мин, ихластыр, һаман ышанып бетмим әле.

— Ә кулбашындагы ләлә чәчкәсе?

— Франциядә ниндидер җинаять эшләп, шуның өчен хурлык тамгасы сугылган бер инглиз хатыны ул.

— Атос, Атос, валлаһи дим, сезнең хатын ул, тышкы билгеләре шул хәтле туры килүен оныттыгызмыни? — диде д'Артаньян.

— Шулай да тегесен үлгән дип уйлыйм, чөнки мин аны бик әйбәтләп асып киткән идем.

Бу юлы д'Артаньянга башын чайкап куярга туры килде.

— Нишләргә соң? — дип сорады ул.

— Гел Дамокл кылычы астында яшәп булмый бит, бу хәлдән котылу юлын табарга кирәк,— диде Атос.

— Ничек соң ул?

— Аның белән күрешеп, аңлашырга тырышып карагыз. «Я татулык, я сугыш! — диегез.— Дворян буларак сүз бирәм: сезнең турыда беркемгә бер сүз әйтмәм, сезгә каршы бернинди яманлык кылмам,— диегез.— Үз тарафыгыздан сез дә миңа каршы яманлык эшләмәскә тантаналы итеп ант итегез. Шулай булмаганда, мин канцлерга чаклы, корольгә чаклы барып җитәрмен, палачын да табармын, бөтен король сараен сезгә каршы котыртырмын, сезнең тамгагыз барлыгын әйтермен, мин сезне суд хөкеменә тапшырырмын, әгәр инде сезне акласалар, ул чагында, дворян буларак сүз бирәм, сезне берәр койма буенда котырган эт урынына үтереп китәчәкмен!» — диегез.

— Андый ысулга каршы түгел мин түгелен, тик аның белән ничек күрешергә соң? — диде д'Артаньян

— Вакыт дигән нәрсә бер җаен китереп чыгарыр әле, дустым, андый җай кешегә икеләтә отыш мөмкинлеге бирә: ника-

дәр зуррак ставка куйсагыз, шулкадәр күбрәк отасыз, күтә белсәгез, билгеле.

— Анысы шулай да, тирә-ягында сине үтерергә, агуларга йөрүчеләр кайнап торганда, көтүе шул...

— Берни булмас! Ходай безне моңарчы саклады бит әле, моннан соң да саклар,— диде Атос.

— Әйе, безне саклады! Әлбәттә, без ир кешеләр, дөресен генә әйткәндә, безнең үлемнән курыкмавыбыз бик табигый, ә менә ул!..— диде егет тавышын әкренәйтә төшеп.

— Кем ул? — дип сорады Атос.

— Констанция.

— Бонасье ханым! Ә, әйе, чыннан да шулай бит әле, оныттып җибәргәнмен: сез бит аңа гашыйк, бичара дускаем!

— Теге үлгән бәндәнең кесәсеннән тапкан хаттан сез аның монастырьда икәнлеген белгәнсез бит! — диде Арамис.— Монастырьларда алай бигүк начар димәс идем мин. Вәгъдәм шул: менә Ларошельне камау гына бетсен, мин үзем...

— Әйе, әйе, Арамис,— диде Атос, аны сүзеннән бүлдереп.— Сезнең күңелегез диндә икәнлеген беләбез.

— Минем мушкетер булып йөрүем вакытлыча гына,— диде Арамис юаш кына.

— Ул үзенең мәгъшукасыннан күптән хат-хәбәр алганы юк шикелле, анысына әһәмият итмәгез, безгә таныш нәрсә инде ул,— дип пышылдады Атос.

— Менә нәрсә! — диде Портос.— Минемчә, моның гади генә бер чарасы бар бит.

— Нинди чара? — дип сорады д'Артаньян.

— Сез аны монастырьда дидегезме әле?

— Әйе.

— Шулай булгач, нигә аптырап калдыгыз? Менә камау гына бетсен, без ул ханымны монастыреннан урлыйбыз да шуның белән вәссәлам.

— Иң әлек аның кайсы монастырьда икәнен белергә кирәк бит әле.

— Анысы да дөрес,— диде Портос.

— Аның өчен монастырьны королева үзе сайлаган дип әйткән идегез түгелме, д'Артаньян дус? — дип сорады Атос.

— Әйе, һич югы, шулай дип уйлыйм мин.

— Бик яхшы! Ул чагында безгә бу эштә Портос ярдәм итәр.

— Ничек итеп, әйтеп бирмәссезме?

— Үзегезнең маркизагыз, герцогинягыз, принцессагыз аркылы. Аның зур бәйләнешләре бар булса кирәк.

— Тссс! — диде Портос, бармагын авызына куеп.— Минемчә, ул — кардинал тарафдары, берни белергә тиеш түгел ул.

— Алай булса, Бонасье ханымны үзем белешермен,— диде Арамис.

— Сезме, Арамис? — диде өч дус бертавыштан.— Ничек итеп белешмәкче буласыз?

— Королеваның рухание аша, мин аның белән бик дус,— диде Арамис кызарынып.

Шушы җирдә дүрт дус, мәҗлесләрен тәмам итеп, аерылыштылар, бүген кич яңадан күрешергә дип сүз куештылар. Д'Артаньян францисканнар монастырена кайтып китте, өч мушкетер исә король ставкасына таба юнәлделәр, анда әле аларның үзләренә урын мәсьәләсен кайгыртасылары бар иде.

## XIII

## «КҮГӘРЧЕН ОЯСЫ» МӘЙХАНӘСЕ

Дошман белән тизрәк кара-каршы очрашырга ашыккан, Бекингэмны кардинал шикелле үк дошман күргән король (герцогны дошман күрү өчен кардиналга караганда нигезе күбрәк иде аның) бу вакытта иң элек инглизләрне Ре атавыннан куу, аннары инде Ларошельне камап алуны тизләтү өчен хәзер үк бөтен боерыкларын бирмәкче иде. Ләкин Бассомпьер һәм Шомберг белән герцог Ангулемлы арасында килеп чыккан низаглар аны бу эшеннән тоткарлап торды.

Бассомпьер белән Шомберг җәнаплары Франциянең маршаллары булып, турыдан-туры король кул астында армиягә командалык итү хокукларын даулыйлар иде; кардинал исә, Бассомпьер рухы-җаны белән һугенот дип, үзенең дин туганнары инглизләр белән ларошельлеләргә каршы әллә ни эш күрсәтмәс дип, бу постка герцог Ангулемлыны тәкъдим итә, король инде аны кардиналның соравы буенча башкомандующийның урынбасары итеп билгеләгән дә иде. Шуңа күрә, Бассомпьер белән Шомберг армиядән китмәсеннәр өчен аларның һәркайсына мөстәкыйль отрядларга командалык итү эшен тапшырырга туры килде: Бассомпьер үзенә Лаледан Домпьерга чаклы төньяк участокны алды, герцог Ангулемлы Домпьердан Периньига хәтле көнбатыш участокны, Шомберг исә Периньидан Ангутенга кадәр көньяк участокны алды.

Герцог Орлеанлының ставкасы Домпьерда.

Король ставкасы әле Этреда, әле Лажаррида иде.

Һәм, ниһаять, кардиналның ставкасы Таш күпер янындагы дюналарда, бернинди ныгытмалар белән дә сакланмаган гади бер йортка урнашкан иде.

Шулай итеп, герцог Орлеанлы Бассомпьерны, король герцог Ангулемлыны, кардинал исә Шомбергны күзәтеп тора иде.

Көчләрне урнаштыру эше тәмамлангач, командование инглизләрне атаудан куу чарасына керешә башлады.

Моның өчен шартлар да җайлы иде: инглизләр яхшы ашаганда яхшы сугышалар; хәлбуки, хәзер аларның ашаганнары тозлы ит белән күксеп беткән сохари гына иде, шуңа күрә

лагерьда байтак кына авырулар да күренә башлады. Өстәвенә, елның бу вакытында бөтен океан яры буйлап давыллаган диңгез көн саен берәр кечерәк судноны ватып-җимереп тора, Эгильон борынынннан алып траншеяга чаклы булган яр буена, океанда су күтәрелгән саен, шлюпка, фелюга һәм башка шундый судно ватыклары тулып кала иде. Шушы хәлләрдән инде, король солдатлары үз лагерьларыннан кузгалмасалар да, үҗәтлеге белән генә атауда яткан Бекингэмга барыбер бүген-ме-иртәгәме камаудан кире чигенергә туры киләчәге аңлашылып тора иде.

Ләкин де Туарак әфәнде «дошман лагеренда яңа һөҗүмгә хәзерлек бара» дигән хәбәрне җиткергәч, король бу хәлгә чик куярга карар итте һәм чын-чынлап сугышырга дип әмер бирде.

Камаў сугышларын җентекләп тасвирлап тормастан, үзебез сөйлисе хәлләргә турыдан-туры бәйләнеше булырлык вакыйгаларны гына китереп, кыскача гына бу эшнең уңышлы булып чыкканлыгын, корольнең моңа бик нык гаҗәпләнгәнлеген һәм кардиналга исә зур шөһрәт китергәнлеген генә әйтеп китик. Инглизләр, әкрен-әкрен кысрыкланып, һәр бәрелеш саен җиңелә торгач, Луа атавыннан чыккан чакта тәмам тар-мар ителеп, яңадан корабларына утырып китәргә мәҗбүр булдылар. Сугыш мәйданында аларның ике меңләп кешесе, болар арасында биш полковник, өч подполковник, ике йөз илле капитан һәм егермеләп атаклы дворян үлеп калды, моннан тыш, дүрт туплары белән алтмыш байраклары калды. Клод де Сен-Симон ул байракларны Парижга алып кайткач, зур тантана белән аларны Париждагы Мәрьям ана чиркәвенең гөмбәзләренә элеп куйдылар.

Башта лагерьда, аннары инде бөтен Франциядә бу җиңү өчен рәхмәт укып гыйбадәт кылдылар.

Шулай итеп, кардиналга хәзер, вакытлыча гына булса да, инглизләр тарафыннан куркыныч булыр дип шикләнмичә, камау эшен дәвам иттерү мөмкинлеге туды.

Ләкин, әле әйткәнебезчә, бу тынычлык кыска гомерле булып чыкты.

Герцог Бекингэмның Монтегю исемле бер курьеры әсир ителеп, шуның аркылы Австрия, Испания, Англия һәм Лотарингия арасында союз барлыгы билгеле булды.

Бу союз Франциягә каршы оештырылган иде.

Ул гына да түгел, Бекингэмның үзе уйлаганнан да ашыгычрак рәвештә ташлап киткән ставкасыннан әлеге союзның барлыгын тагын бер тапкыр раслый торган документлар табылды, һәм бу кәгазьләр, кардиналның «Мемуарлар»ында әйтүенә караганда, Шеврез ханымга, димәк, королевага да шик төшерә икән.

Моның өчен бөтен җаваплылык хәзер кардинал өстенә төшә, чөнки үз өстенә җаваплылык алмый торып тулы хаки-

миятле министр булып булмый иде. Шуңа күрә ул, күп мәгълүматлы акылының бөтен көчен җигеп, Европадагы теге яки бу зур дәүләттә барган аз гына үзгәрешләрне дә көн-төн күзәтеп тора башлады.

Кардиналга Бекингэмның энергиясе, бигрәк тә нәфрәт көче мәгълүм иде. Әгәр Франциягә каршы оешкан союз җиңүгә ирешсә, кардиналның бөтен булган йогынтысы юкка чыгар иде: ул чагында Испания белән Австрия политикасы Лувр кабинетында үзенең даими вәкилләрен булдырыр иде, хәзергә исә анда аның аерым тарафдарлары гына бар иде. Шуннан соң инде ул, ягъни Ришелье, француз министры, бигрәк тә милли министр буларак, бөтенләй юкка чыгар иде. Сабый бала кебек аңа буйсынган һәм, сабый бала усал укытучысын яратмаган кебек, аны күрә алмаган король кардиналны шәхси үч алырга омтылган энесе белән королева кулына тапшырыр иде; кыскасы, кардинал бетәр иде һәм, ихтимал, аның белән бергә Франция дә харап ителер иде. Мондый хәлне, әлбәттә, булдырмаска кирәк иде.

Шуңа күрә кардинал үзенә резиденция итеп сайлаган Таш күпер янындагы кечкенә йортта көн-төн курьерлар алмашынып тора, өстәвенә, минут саен аларның саны да арта бара иде.

Болар — җиләннәрен килешсез генә итеп кигән монахлар, киемнәреннән аларның чиркәү әһелләре, тик сугыш чиркәвенеке икәнлекләре күренеп тора иде; шулай ук кысанрак итеп паж киеме кигән, гәүдә йомрылыклары киң чалбар аркылы да беленеп торган хатын-кызлар һәм, ниһаять, шапшак куллы, төз-ыспай буйлы крестьяннар, боларының инде бай нәсел кешеләре икәнлеген бер чакрымнан ук белеп булырлык иде.

Бу йортка күңелсезрәк визитлар да булгалаган, күрәсең, чөнки ике-өч тапкыр кардиналны үтерергә маташканнар, имеш, дигән хәбәрләр дә ишетелгәләде.

Дөрес анысы, кардинал хәзрәтләренең дошманнары: кирәге чыкканда үзе дә көч кулланып эш итү өчен әлеге булдыксыз кешеләрне ул үзе яллаган икән, дип тә сөйләделәр; хәер, министрлар әйткәнгә дә, аларның дошманнары сүзенә дә ышанып бетәргә ярамый.

Мәгәр герцог Ангулемлыга кайбер мөһим боерыклар тапшыру, король белән берәр нәрсә киңәшү яки әлеге йортына китерергә теләмәгән берәр йомышчы белән күрешеп сөйләшү өчен төнлә атта йөреп кайтырга кардиналга боларның берсе дә комачаулык итми — аны иң дошман күрүче кешеләр дә кардиналның батыр йөрәкле бер кеше икәнлеген танымый калмыйлар иде.

Мушкетерларга килсәк, Ларошельне камаган вакытта әллә ни эшләре булмаганлыктан, алар, тәртип ягыннан бигүк кысылмыйча, күңелле генә яшәп яталар иде. Мушкетерлар, бигрәк тә безнең өч дус, де Тревиль әфәнде белән дус булганлык-

тан, лагерьга соңга калып, утлар сүнгәч кенә кайтып керергә аңардан еш кына махсус рөхсәт тә алгалыйлар иде.

Шулай бер кичне, д'Артаньян траншеяда каравылда торып, дусларына ияреп алмаган көнне, Атос, Портос һәм Арамис, гаскәри атларында, поход плащларына төренгән килеш, пистолетларын атарга әзер тотып, өчәү «Күгәрчен оясы» дигән мәйханәдән кайтып киләләр иде,— бу мәйханәне моннан ике көн элек Лажарридан кайткан чагында Атос тапкан иде. Әйткәнебезчә, һәр минутта берәр засада очратырга әзер булып кайтып килгән чакларында кинәт алар Буанар авылыннан чирек лье чамасы ераклыкта ат аягы тавышлары ишеттеләр; өчесе дә шундук туктап, юл уртасына тупланышып бастылар; бераздан, болыт астыннан килеп чыккан ай яктысында, борылышта ике җайдак күренде,— алар каршыга килгән чакта боларны күреп туктаганнар да барыргамы, әллә кире китәргәме дип киңәшеп торалар иде булса кирәк. Аларның болай икеләнеп калулары өч дуска беркадәр шикле тоелды, шуңа күрә Атос берничә адым алгарак чыкты да боеручан тавышы белән:

— Кемнәр ул? — дип кычкырып сорады.

Тегеләрнең дә берсе үз нәүбәтендә:

— Ә сез үзегез кемнәр? — дип сорады.

— Җавап түгел бу! — диде Атос моңа каршы.— Кемнәр сез? Җавап бирмәсәгез, ата башлыйбыз.

Боерырга, әмер бирергә өйрәнгән яңгыравык бер тавыш:

— Алай эшләргә киңәш итмим, әфәнделәр! — диде шуннан соң.

— Бу — берәр өлкән офицер булса кирәк, төнлә тикшереп-карап йөрүедер, нишлибез, әфәнделәр? — диде Атос әкрен генә.

— Кемнәр буласыз сез? — дип сорады боеручан тавыш.— Җавап бирмәсәгез, буйсынмаганыгыз өчен үкенергә туры килер.

Атос, шушы сүзне әйтүченең андый сорау бирергә хаклы кеше булуына ышана башлап:

— Король мушкетерлары без,— диде.

— Кайсы ротаныкы?

— Де Тревиль ротасыннан.

— Тиешле якынлыкка килегез дә төнлә монда нишләп йөрүегезне әйтеп бирегез.

Өч иптәш, юашлана төшеп, якынрак килделәр, чөнки хәзер өчесе дә үзләреннән көчлерәк бер кеше белән эш иткәнлекләрен белеп торалар иде; барысы исеменнән Атос сөйләшәчәк иде.

Ике җайдакның берсе, икенче булып эндәшкәне, үзенең юлдашыннан бер ун адымга алдарак тора иде; Атос кулын изәп кенә Портос белән Арамиска да арткарак калырга кушып, бу кешенең янына үзе генә килде.

— Гафу итегез, офицер әфәнде, без кем белән эш иткәне-

безне белмичәрәк тордык, шулай да әзер тора идек,— диде Атос.

— Сезнең исемегез? — диде офицер, йөзен яртылаш плащы белән каплаган иде ул.

— Шулай да, әфәндем, миннән болай сорау алырга хакыгыз барлыгына берәр дәлил китерсәгез иде,— диде Атос, бу хәлгә үртәлә башлап.

Әлеге җайдак:

— Исемегез? — дип кабат сорады да плащ башлыгын күтәреп йөзен ача төште.

— Кардинал җәнаплары! — дип гаҗәпләнеп әйтеп куйды мушкетер.

Кардинал:

— Исемегез? — дип өченче тапкыр сорады.

— Атос,— диде мушкетер.

Кардинал кулы белән ишарәләп кенә юлдашын чакырды, тегесе тиз генә аның янына килде.

— Бу өч мушкетер безне озата барырлар,— диде кардинал әкренрәк тавыш белән.— Лагерьда минем чыгып китүемне белмәсеннәр. Болар безнең белән китсәләр, ул хакта кайтып әйтмәячәкләренә ышанып йөри алабыз.

— Галиҗәнап, без — дворяннар, бездән ул хакта сүз бирдертегез дә шуннан соң борчылмассыз, тыныч булырсыз. Аллага шөкер, сер саклый беләбез без,— диде Атос.

Кардинал кыю әңгәмәдәшенә үткен карашын төбәде.

— Колагыгыз бик сизгер икән, Атос әфәнде,— диде кардинал.— Хәзер инде сез мин әйткәнне тыңлагыз: үземне озата барырга дипюем сезгә ышанмаудан түгел, үземә куркынычсызрак булсын өчен үтенәм мин аны. Сезнең юлдашларыгыз, әлбәттә, Портос әфәнде белән Арамис әфәндедер, шулаймы?

— Шулай, галиҗәнап хәзрәтләре,— диде Атос. Шул чагында арттарак торган ике мушкетер да, эшләпәләрен кулларына тотып, якынрак килделәр.

— Мин сезне беләм, әфәнделәр, сезне беләм мин,— диде кардинал.— Сезнең минем дусларым исәбенә кермәвегезне дә беләм, һәм анысы минем өчен бер дә күңелле хәл түгел; әмма мин сезнең батыр йөрәкле, намуслы дворяннар булуыгызны һәм сезгә ышанырга мөмкин икәнен дә беләм. Шулай итеп, Атос әфәнде, ике юлдашыгыз белән мине озата баруыгызны үтенәм. Шуннан соң инде, юлда король хәзрәтләре очраса, аны да көнләштерерлек сагым булачак минем.

Мушкетерларның һәркайсы атының муенына тия язып баш иде.

— Ант итеп әйтәм, галиҗәнап хәзрәтләре, безне үзегез белән ияртеп бик яхшы эшлисез сез: юлда килгәндә безгә берничә куркыныч бәндә очрады, «Күгәрчен оясы»нда шуларның дүртесе белән җәнҗаллашып та алдык хәтта,— диде Атос.

— Җәнҗал? Нәрсә аркасында ул, әфәнделәр? — дип сорады кардинал.— Минем бер дә җәнҗал яратмаганымны беләсез бит.

— Менә шуңа күрә дә булган хәл турында сез галиҗәнап хәзрәтләрен искәртеп куярга телим. Югыйсә, сезнең ул хәлне башка кешеләрдән ишетеп, булганны дөрес яктыртмау сәбәпле, безне гаепле санавыгыз ихтимал иде.

— Ә ул җәнҗалның азагы ни белән бетте соң? — дип сорады кардинал, кашларын җыерып.

— Менә каршыгызда торган дустым Арамисны кылыч белән бераз беләген яраладылар, әгәр сез галиҗәнап хәзрәтләре штурмга барырга әмер бирсәгез, аның ул ярасы иртәгә үк һөҗүмгә барырга бер дә комачауламаячак, анысына, галиҗәнап хәзрәтләре, үз күзегез белән күреп ышанырсыз.

— Әмма сез бит кылыч белән кадаганга җавап кайтармый кала торган кешеләр түгел,— диде кардинал бу сүзгә каршы.— Карагыз әле, әфәнделәрем, яшерми генә дөресен әйтегез әле — алар кадаганда сез дә тик кенә тормагансыздыр бит? Чын-ихлас күңелдән сөйләгез, минем гөнаһларны кичерү хокукым барлыгы сезгә мәгълүм.

— Галиҗәнап, мин кылычыма орынмадым да — дошманымны кочагыма күтәреп алып тәрәзәдән тышка гына ыргыттым,— диде Атос һәм шуннан соң беркадәр икеләнебрәк әйтә куйды:— Җиргә барып төшүгә аягын сындырды бугай.

— Әһә! — дип куйды кардинал.— Ә сез, Портос әфәнде?

— Галиҗәнап, мин дуэльнең тыелган эш икәнлеген беләм, шуңа күрә кулыма урындык алдым да разбойникларның берсенә дөнкелдәттем, кулбашын имгәттем бугай.

— Алай...— диде кардинал.— Ә сез, Арамис әфәнде?

— Галиҗәнап, мин бик юаш кеше инде, шуның өстенә әле, монах булырга да җыенам, монысы, бәлки, сез галиҗәнап хәзрәтләренә мәгълүм дә түгелдер. Шуңа күрә мин иптәшләремне ничек тә тыеп калырга тырышкан идем, тик әлеге әшәке бәндәләрнең берсе астыртын рәвештә кылычы белән сул беләгемә китереп кадады. Шуннан инде минем дә түзеп торырлыгым калмады, мин дә кылычымны суырып чыгардым. Теге адәм яңадан өстемә ташлангач, ул минем кылыч очына бөтен гәүдәсе белән килеп кадалган кебек тоелды. Шулай булгандырмы, анысын тәгаен әйтә алмыйм, әмма аның егылганын бик яхшы хәтерлим, аны да калган икесе белән бергә алып киттеләр шикелле.

— Шайтан алгыры, трактир җәнҗалы аркасында өч кеше сафтан чыккан!..— дип куйды кардинал.— Шулай шул, әфәнделәр, сез шаяртырга яратмыйсыз. Ул бәхәс нидән килеп чыкты соң?

— Ул бәндәләр исерек иде,— диде Атос.— Алар кич кунакханәгә ниндидер бер хатын-кыз килгәнен белгәннәр дә шуның янына бәреп кермәкче булганнар.

— Бәреп кермәкче булганнар? — дип кайтарып сорады кардинал.— Нинди максат белән?

— Ирексезләү максаты белән, күрәсең,— диде Атос.— Мин бит сез галиҗәнап хәзрәтләренә аларның исерек булуларын әйткән идем инде.

— Ул хатын яшь, чибәр булганмы? — дип сорады кардинал беркадәр борчыла төшеп.

— Без аның үзен күрмәдек, галиҗәнап,— диде Атос.

— Әһә, сез аны күрмәдегезмени? Бик яхшы алайса,— дип, тиз генә әйтеп куйды кардинал.— Хатын-кызның абруен саклап бик яхшы иткәнсез. Мин үзем дә хәзер шул «Күгәрчен оясы»на барам, сез сөйләгәннең дөреслеген сорашып белермен.

— Галиҗәнап, без дворяннар, җаныбызны коткарырга кирәк булса да алдашмас идек,— диде Атос горур гына.

— Сез сөйләгәннәрнең дөреслегенә шикләнмим, Атос әфәнде, тамчы да шикләнмим...— Шуннан соң кардинал, сүзне ахырга кадәр кучерү өчен, болай дип сорады: — Шулай да әйтегез әле: ул хатын ялгызы гына идеме әллә?

— Ул хатын янында бүлмәдә бер ир кеше дә бар иде. Тавыш була торып та чыкмагач, ул ир куркак бер кеше булырга тиеш,— диде Атос.

— Изге китапта «алай бик ашыгып хөкем чыгармагыз» дип әйтелгән,— диде кардинал бу сүзгә каршы.

Атос гафу үтенеп баш иде.

— Ярый, әфәнделәр, булды. Белергә теләгәнемне белдем. Минем арттан иярегез,— диде кардинал.

Өч мушкетер кардиналны алга уздырып җибәрделәр; кардинал яңадан йөзен башлыгы белән каплады, атын атлатып, дүрт юлдашыннан тугыз-ун адым чамасы алданрак китте.

Озакламый отряд трактирга килеп җитте; мөсафирханә бер кешесез, тып-тын кебек иде: хуҗасы, үзенә нинди атаклы кунак киләсен белеп, башка әрсез кунакларны алдан ук озатып бетергән иде, күрәсең.

Ишеккә ун адым чамасы кала, кардинал ишарәләп кенә үзенең юлдашы белән өч мушкетерга туктарга кушты. Тәрәзә капкачына бер иярле ат бәйләп куелган иде; кардинал шартлы билге белән өч тапкыр тәрәзәне шакыды. Плащка төренгән бер кеше шундук йорттан чыгып, кардинал белән нидер сөйләшеп алды да, атка атланып, Сюржер юлыннан чаптырып китеп барды. Бу юл белән Парижга да барып була иде.

— Якынрак килегез, әфәнделәр,— диде кардинал.— Сөйләгәнегез дөрес икән, мушкетер әфәнделәр,— диде ул өч дуска эндәшеп.— Сезгә яхшылык кылу минем теләктә булганлыктан, безнең бу очрашу сезгә файда гына китерер. Ә хәзер минем арттан иярегез.

Кардинал атыннан җиргә төште, мушкетерлар да төштеләр; кардинал атының тезгенен юлдашына бирде, өч мушкетер атларын тәрәзә капкачларына бәйләп куйдылар.

Трактирчы бусага төбендә басып тора — анын өчен кардинал дамасы белән көрешергә килгән бер офицер гына иде.

— Бу әфәнделәргә камин янында җылынып мине көтеп торырга аста берәр бүлмәгез юкмы сезнең? — диде кардинал.

Трактирчы зур гына бер бүлмәнең ишеген ачып җибәрде. Бу бүлмәгә элекке начар гына миче урынына бик әйбәт зур камин чыгарганнар иде.

— Менә шушы,— диде трактирчы.

— Яхшы,— диде кардинал.— Әфәнделәр, менә шунда керегез дә мине бераз көтеп торыгыз — мин сезне ярты сәгатьтән дә артык тоткарламам.

Мушкетерлар аскы каттагы зур бүлмәгә керә башлауга, кардинал, бүтән берни дә сорау бирмәстән, тиз-тиз генә баскычтан өскә менеп китте. Мондагы юлларны ул бик яхшы белә иде, күрәсең.

## XIV

## МИЧ ТОРБАСЫНЫҢ ФАЙДАСЫ

Безнең өч дусның кардинал химаячелек иткән ниндидер бер ханымга, үзләре дә белмәстән, фәкать рыцарьлык тойгысы һәм батыр йөрәкле булулары аркасында гына ярдәм күрсәткәнлекләре аңлашылып тора иде.

Ләкин кем икән соң әлеге ханым? Иң элек шул сорау өч мушкетерны уйга калдырды. Аны ничек кенә итеп фараз кылсалар да, берсе дә канәгатьләнерлек түгел икәнлеген күргәч, Портос мөсафирханә хуҗасын чакырып алып, уйнар өчен шакмак китерергә кушты.

Портос белән Арамис, өстәл янына утырып, шакмак уйнарга керештеләр. Атос уйлана-уйлана әкрен генә арлы-бирле йөренә башлады.

Ул энә шулай яртылаш сүтелгән мичнең торбасы яныннан йөренгәләп тора иде; торбаның югарыгы башы өске каттагы бүлмәгә чыга иде. Торба яныннан узган саен Атоска шуннан кемнәрнеңдер мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелде һәм ахырда бу тавыш аны кызыксындыра башлады. Атос якынрак килеп тавышка колак салды, тегеләрнең берничә сүзен ачык ишеткәч, бик кызык булып китте, иптәшләренә «тавышланмагыз!» дип ишарә ясады, шуннан иелеп колагын торба авызына куйды да тынып калды.

— Карагыз әле, миледи, бик зарур эш бу. Менә монда утырыгыз да сөйләшик әле,— диде кардинал.

— Миледи! — дип пышылдап куйды Атос.

— Зур игътибар белән тыңлыйм, галиҗәнап хәзрәтләре,— дип җавап бирде бер хатын-кыз. Бу тавышны ишеткәч, мушкетер калтыранып куйды.

— Шаранта тамагына җитәрәк, Ла Пуант форты янында сезне кечерәк бер судно көтеп тора. Командасы — инглизләр, капитаны миңа бик тугрылыклы кеше. Иртәгә иртән якорьдан кузгалып китәчәк.

— Алай булгач, миңа, димәк, бүген кич чыгып китәргә кирәк анда.

— Шушы минутта ук, ягъни миннән күрсәтмәләр алу белән үк. Моннан чыкканда сезгә ишек төбендә ике кеше очрар, шулар сезне юлда саклап барырлар. Башта мин чыгып китәм. Аннары, бер ярты сәгать чамасы көткәч, сез чыгарсыз.

— Яхшы, галиҗәнап. Шулай да сез миңа тапшырачак йомышыгызга әйләнеп кайтыйк әле. Мин киләчәктә дә сез галиҗәнап хәзрәтләренең ышанычына лаеклы булып калырга телим, шуңа күрә, минем тарафтан берәр ялгышлык эшләнмәсен өчен, ул йомышны миңа ачык һәм төгәл итеп сөйләп-төшендереп бирсәгез иде.

Сөйләшүчеләр арасында беравыкка тирән тынлык урнашты; сизелеп тора: кардинал сүзләрен уйлап-сайлап кына әйтергә җыена, миледи исә, аның әйткәнен төшенеп хәтерендә калдыру өчен, бөтен игътибарын тупларга тырыша иде.

Атос, шул арадан файдаланып, иптәшләренә ишекне эчтән бикләп алырга кушты да ишарәләп кенә үзе янына чакырып, бергәләп тыңларга тәкъдим итте.

Җайлап утырырга яраткан ике мушкетер үзләренә дә, Атоска да урындыклар алып килделәр. Өчәүләшеп, башларын берберсенә якын китереп һәм колакларын торгызып, торба янына урнаштылар.

— Сез Лондонга барасыз. Анда Бекингэм янына керәсез...— дип сүзендә дәвам итте кардинал.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, әйтим әле,— диде миледи,— теге асылташ вакыйгасыннан соң ул галиҗәнап миңа шик тота. Герцог шул эшкә минем дә катнашым бар дип саный.

— Бу юлы аның ышанычын казану турында бармый сүз, сез аның янына ачыктан-ачык һәм бернинди риясыз арадашчы булып барасыз,— диде кардинал бу сүзгә каршы.

Миледи беркадәр киная белән:

— Ачыктан-ачык һәм бернинди риясыз,— дип куйды.

— Әйе, ачыктан-ачык һәм бернинди риясыз,— дип җөпләде кардинал шул ук тон белән.— Бу сөйләшү ачыктан-ачык булырга тиеш.

— Сез галиҗәнап хәзрәтләренең күрсәтмәсен мин нәкъ үзегез кушканча үтәрмен һәм аны үтәргә әзер булып көтеп торам.

— Сез минем исемнән Бекингэм янына барасыз да әйтәсез: аның ничек сугышка хәзерләнүе барысы да мәгълүм миңа, аның ул хәзерлеге мине әллә ни борчымый: әгәр ул җөрьәт итеп беренче адымын ясый икән, мин королеваны харап итәчәкмен.

— Сез галиҗанап хәзрәтләренең моны чынга ашыра алуына ышаныр микән соң ул?

— Ышаныр, минем моңа дәлилләрем бар.

— Минем ул дәлилләрне аңа әйтүем һәм аның шуларны үлчәп каравы да кирәк бит.

— Әлбәттә. Сез аңа коннетабль хатыны бал-маскарад биргән кичне герцог белән королеваның коннетабль хатыны бүлмәсендә очрашулары турында Буа-Робер белән маркиз де Ботрюның донесениеләрен игълан итәчәгемне әйтерсез. Бу хакта бернинди шик-шөбһәсе калмасын өчен, сез аның бал-маскарадка Бөек Могол киеменнән килгәнлеген әйтерсез. Ул киемне бал-маскарадка кавалер де Гиз киеп барырга җыенган булган, ә герцог аны де Гиздан өч мең пистоль акчага сатып алган...

— Яхшы, галиҗанап.

— Аның король сараена ничек кергәнлеге һәм аннары төнлә ничек чыгып киткәнлеге бөтен ваклыгына хәтле миңа мәгълүм. Фалчы киеме киеп кергән ул анда. Минем мәгълүматларымның дөреслегенә тәмам ышандыру өчен сез аңа әйтерсез: плащ эченнән ул кара елтыравык сыман яшь тамчылары, баш сөякләре һәм аркылы-торкылы сөяк сурәтләре белән чуарланган киң итәкле ак күлмәк кигән булган, көтелмәгән бер-бер хәл килеп чыга калса, үзен Луврда берәр зур вакыйга алдыннан пәйда була торган Ак Даманың өрәге итеп күрсәтмәкче булган...

— Әйтеп бетердегезме, галиҗанап?

— Әйтегез аңа: мин аның Амьендагы маҗараларын да бөтен вагы-төягенә хәтле беләм. Мин аның ул маҗараларын кечерәк бер роман итеп яздырам, андагы бакчаны һәм әлеге төнге хәлнең төп каһарманнарының сурәтләрен тасвирлатам.

— Әйтермен мин аны.

— Тагын шунсын да әйтегез: Монтегю минем кулда, Монтегю Бастилиядә, тентегәндә аңардан бернинди хат-мазар чыкмаса да, җәзалый башлагач, ул бөтен белгәнен... хәтта белмәгәннәрен дә әйтер.

— Бик яхшы.

— Һәм иң соңгысы, шунысын да өстәп әйтегез: герцог ашыга-ашыга Ре атавыннан киткән чагында квартирында де Шеврез ханымның бер хатын онытып калдырган. Бу хат королеваның йөзенә бик зур тап төшерә, чөнки әлеге хат королеваның корольнең дошманнарын яратуын гына түгел, бәлки Франциянең дошманнары белән заговорда булуын да раслый. Сез мин әйткәннәрнең барысын да яхшы хәтерләдегез шикелле, шулаймы?

— Менә үзегез тикшереп карагыз, галиҗанап хәзрәтләре: коннетабльнең хатыны җыйган бал, Луврдагы төнге хәл, Амьен киче, Монтегюны кулга алу, де Шеврез ханым хаты.

— Дөрес, бик дөрес. Хәтерегез бик яхшы икән, миледи.

— Әгәр герцог, бу дәлилләрнең берсенә дә ышанмыйча, үз

сүзендә калса һәм һаман да Франциягә сугыш куркынычы белән янаса? — диде кардиналның мактавын ишеткән ханым.

— Герцог ул шашкан бер кеше кебек, дөресрәге, дивана бер кеше кебек гашыйк булган,— диде кардинал тирән бер пошыну белән.— Борынгы заман паладиннары * кебек, бу сугышны ул сөйгән дамасының мәхәббәтле карашына лаек булу өчен генә башлады бит. Әгәр ул сугышның, үзе әйткәнчә, аның уйтойгыларына хуҗа булган ханымның абруе һәм, ихтимал, иреге дә бәрабәренә төшәчәген белсә, ихластыр, иң элек, бу сугышны дәвам иттерергәме-юкмы дип уйларга тиеш булачак.

— Шулай да, әгәр ул һаман үз сүзендә торса? — диде миледи, үзенә йөкләнгән эшне азагына кадәр ачыкларга тырышканлыгын күрсәтеп.

— Һаман үз сүзендә торсамы? — дип кабатлады кардинал.— Андый хәлнең булуы бик икеле.

— Булуы да мөмкин бит.

— Әгәр ул һаман үз сүзендә торса...— Кардинал бер тын уйланып торды да сүзен дәвам иттерде:— Әгәр һаман үз сүзендә торса, ул чагында мин дәүләтнең йөзен үзгәртә торган берәр хәл эшләүгә дә өмет тота алам.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, әгәр сез миңа тарихта булган шундый хәлләрне мисал итеп әйтә алсагыз, мин, ихтимал, сезнең бу ышанычыгызны уртаклашыр да идем,— диде миледи.

— Әйтик, менә сезгә бер мисал,— диде Ришелье.— 1610 елда, данлыклы король Һенрих Дүртенче, герцогныкы шикелле үк диярлек ният белән, бер үк вакытта Франция белән Италиягә басып кереп, Австриягә берьюлы ике тарафтан китереп бәрергә җыенгач, Австрияне коткарып калырлык хәл булмаганмы? Императорга бәхет килеп чыккан кебек, Франция короленә дә бәхет чыкмас микәнни?

— Галиҗәнап хәзрәтләре Бакырчылар урамындагы хәнҗәр белән кадап үтерүне әйтә торгандыр?

— Әйе.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, Равальяк ** шикелле эшләргә ниятләүчеләрне аның җәзалап үтерелүе куркытадыр дип шикләнмисезме?

— Бөтен заманда да, барлык дәүләтләрдә дә, бигрәк тә ул дәүләтләр арасында дин дошманлыгы яшәсә, җәзаланып үлүдән курыкмаучы фанатиклар булмый калмый. Беләсезме, әле менә хәзер генә исемә төште: пуританнар герцог Бекингэмга бик яман ачу тоталар, аларның вәгазьчеләре герцогны антихрист дип атыйлар.

— Я, шуннан нәрсә инде? — дип сорады миледи.

---

* Турылыклы рыцарь.

** Равальяк — (1578—1610) католицизмның фанатик бер тарафдары. 1610 елда Франция короле Һенрих Дүртенчене үтергән.

— Шуннан шул,— дип, салкын гына тавыш белән дәвам итте кардинал,— менә хәзер, мәсәлән, герцогтан үч кайтарырга теләгән яшь, чибәр һәм чая бер хатын-кыз булу да җитеп торыр иде. Андый хатын-кызны табуы кыен түгел: герцогны хатын-кызлар бик ярата, әгәр ул мәңге ташламам дип ант итеп бик күп хатын-кызның йөрәгендә мәхәббәт уты кабызган икән, шулай ук ул гел хыянәт итүе белән бик күпләрдә нәфрәт тә уяткан.

— Әлбәттә, андый хатын-кызның табылуы мөмкин,— диде миледи салкын гына.

— Табылгач, ул хатын, берәр фанатикның кулына Жак Клеман яки Равальяк хәнҗәрен тоттырып, Францияне коткарып калыр иде.

— Аңысы шулай, әмма ул хатын үзе дә җинаятькә катнашучы булып чыгар иде бит.

— Ә менә Равальяк белән Жак Клеманга ярдәм итүчеләрнең исемнәре фаш булганмы соң?

— Юк. Ихтимал, ул кешеләр бик югары дәрәҗәле булганлыктан, аларны фаш итәргә кыймаганнардыр. Галиҗәнап, һәркем өчен дә суд палатасын яндырмыйлар бит.

— Суд палатасының януын очраклы бер хәл генә дип уйламыйсызмы? — диде Ришелье, бернинди мәгънәсе булмаган бер сорау биргән кебек кенә итеп.

— Мин үзем шәхсән берничек тә уйламыйм, галиҗәнап,— диде миледи.— Мин фәкать фактны гына әйтәм. Әгәр дә мин мадмуазель де Монпансье яки королева Мария Медичи булсам, менә хәзер гади леди Кларик булгандагыга караганда саклану чарасын азрак күрер идем дим.

— Сүзегез хак,— диде Ришелье килешеп.— Шулай да сезнең нинди теләгегез бар соң?

— Франция файдасы өчен кирәк дип кылган бөтен эшемне алдан ук раслый торган әмер алыр идем мин.

— Иң элек герцогтан үч кайтарырга теләрдәй хатынны табарга кирәк бит.

— Андый хатын бар,— диде миледи.

— Аннары ходайның хөкемен җиренә җиткерердәй адәм актыгы бер фанатик табарга кирәк.

— Аңысы табылыр.

— Менә ул чагында инде сез теләгән әмерне алыр вакыт җитәр.

— Сез хаклы, галиҗәнап хәзрәтләре,— диде миледи,— миңа тапшырган йомышыгызны булган кадәресе белән генә чикләнми дип уйлап мин ялгышканмын. Димәк, мин ул галиҗәнапка шуларны әйтергә тиешмен: аның королева янына коннетабль хатыны оештырган маскарадка ничек киенеп керүе бөтен ваклыкларына хәтле сезгә мәгълүм; Луврда королеваның бер итальян фалчысы белән күрешкәнлегенә сезнең дәлилләрегез бар, ул фалчы герцог Беккингэм булган; сез аның Амьендагы

мажаралары темасына, ул маҗаралар булган бакчаның планын һәм шуңа катнашучыларның сурәтләрен тасвирлатып, кечерәк бер маҗаралы роман яздырасыз; Монтегю Бастилиядә, аны җәзалап, бөтен белгәнен, хәтта онытканнарын да әйттерәчәксез; һәм иң соңгысы — сезнең кулда де Шеврез ханымның бер хаты бар, ул галиҗәнапның квартирыннан табылган әлеге хат аны язган ханымның үзен генә түгел, яздырган ханымны да фаш итә. Аннары, әгәр инде шушыларның барысына да карамастан, герцог һаман үз сүзендә торса, минем йомышым әле әйтелгәннәр белән генә чикләнгән булганлыктан, миңа инде ходайдан Франциияне коткарырлык берәр могҗиза кылсын иде дип кенә ялварырга кала. Шулаймы, галиҗәнап хәзрәтләре, шуннан бүтән бернәрсә дә эшләргә кирәк түгелме миңа?

— Әйе, шулай,— диде кардинал коры гына итеп.

— Ә хәзер,— дип сүзендә дәвам итте миледи, кардиналның икенче тон белән сөйләшә башлаганын сизмәгән дә кебек,— хәзер, сез галиҗәнап хәзрәтләренең дошманнарына карата күрсәтмәләрен алганнан соң, миңа үз дошманнарым турында да бер-ике сүз әйтергә рөхсәт итмәссезме?

— Сезнең дошманнарыгыз бармыни?

— Бар шул, галиҗәнап, ул дошманнарыма каршы сез миңа бөтен булган ярдәмегезне күрсәтергә тиешсез, чөнки мин аларны сез галиҗәнап хәзрәтләренә хезмәт итү дәверемдә булдырдым.

— Кемнәр алар?

— Беренчедән, вак интриганка Бонасье дигән берәү.

— Мант төрмәсендә ул.

— Дөресрәге, ул анда иде, ләкин королева, корольдән боерык алып, ул хатынны монастырьга күчерткән,— диде миледи бу сүзгә каршы.

— Монастырьга?

— Әйе, монастырьга.

— Кайсы монастырьга?

— Белмим, анысын бик зур сер итеп саклыйлар.

— Мин ул серне белермен!

— Аннары ул хатынның кайсы монастырьда икәнлеген миңа әйтерсезме, галиҗәнап хәзрәтләре?

— Бу эш өчен бернинди дә комачаулык күрмим.

— Яхшы... Әмма минем ул бернигә тормаслык Бонасьега караганда күп өлеш хәтәррәк икенче бер дошманым да бар.

— Кем ул?

— Әлеге хатынның сөйгән егете.

— Исеме ничек?

— О, галиҗәнап хәзрәтләре, сез аны бик яхшы беләсез! — дип кычкырып әйтеп куйды миледи, ачуы кузгалып.— Безнен икебезнең дә явыз газраилебез ул: шул кешенең катнашуы аркасында король мушкетерлары, бервакыт сугышып китеп,

сез галиҗәнап хәзрәтләренең гвардиячеләрен җиңгәннәр иде, шул кеше сезнең атчабарыгыз де Вардка өч тапкыр кылыч белән кадап, теге асылташларга бәйләнешле эшне бозган иде; ниһаять, шул кеше, минем Бонасье ханымны урлаганымны белгәч, мине үтерәм дип ант иткән.

— Ә-ә...— дип куйды кардинал.— Кем турында сөйләгәнегезне беләм.

— Мин әнә шул җүнсез адәм д'Артаньянны әйтәм.

— Бик кыю егет ул.

— Шуңа күрә аннан бик сак булырга кирәк.

— Аның Бекингэм белән яшерен мөнәсәбәтләре барлыгына дәлил кирәк иде.

— Дәлил! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды миледи.— Берне түгел, ун дәлил табам.

— Алайса бик ансат эшлибез аны: сез миңа шул дәлилләрне китерегез дә, мин аны Бастилиягә утыртам.

— Яхшы, галиҗәнап, ә шуннан соң?

— Бастилиягә әләгүчеләр өчен бернинди «шуннан соң»ы юк, — диде кардинал тонык бер тавыш белән.— Ах, шайтан алгыры,— дип куйды аннары,— мин менә сезне дошманнарыгыздан коткарган кебек, үз дошманымнан да җиңел генә котыла алсам икән һәм сез миннән шундый кешеләргә каршы кылган гамәлләрегез өчен җәза бирмәвебезне сорасагыз икән!

— Галиҗәнап, әйдәгез алмашабыз — җан бәрабәренә җан, кеше бәрабәренә кеше: сез миңа моны бирегез — мин сезгә тегене, башканы бирәм,— диде миледи.

— Сез нәрсә әйтергә телисездер — белмим,— диде кардинал,— белергә теләмим дә, тик шулай да сезгә бер илтифат күрсәтәсем килә, һәм мин сезнең әлеге җүнсез адәм хакында әйткән үтенечегезне үтәмәслек сәбәп күрмим, ул д'Артаньян, үзегез әйткәнчә, бозык, дуэльче һәм хыянәтче бер кеше булгач — бигрәк тә.

— Намуссыз кеше ул, галиҗәнап, намуссыз кеше!

— Миңа кәгазь, каләм һәм кара бирегез әле.

— Менә шулай, галиҗәнап.

Беравыкка тынып калдылар, кардинал күңеленнән әлеге хатның сүзләрен уйлый яки аны язып утыра иде.

Бу сөйләшүне һәр сүзенә хәтле ишетеп торган Атос иптәшләрен кулларыннан тотты да бүлмәнең икенче башына алып китте.

— Я, нәрсә кирәк соң сиңа, нигә безгә тыңлап бетерергә бирмисең? — диде Портос, ачуы килеп.

— Әкренрәк! — дип пышылдады Атос.— Без үзебезгә кирәкнең барысын да белдек. Хәер, мин сезгә аларның сөйләшүләрен тыңлап бетерергә комачауламыйм, ә минем үземә китәргә кирәк.

— Сиңа китәргә кирәк? — дип кайтарып сорады Портос.—

Әгәр кардинал сине кайда дип сораса, без ни дип җавап бирербез соң?

— Аның мине сораганын көтеп тормагыз, үзегез әйтегез: мин алдан күзәтеп китәм, чөнки хуҗабызның кайбер искәрмәләреннән миндә юл бигүк куркынычсыз түгел дигән шик туды. Өстәвенә, мин ул хакта кардиналның коралчысына да әйтеп куям. Калганы инде минем эш, анысы өчен син бер дә борчылма.

— Сак булыгыз, Атос! — диде Арамис.

— Бер дә борчылмагыз. Үзегезгә мәгълүм, мин үземне үзем тота беләм,— дип җавап бирде Атос.

Портос белән Арамис яңадан мич торбасы янына барып утырдылар.

Атоска килгәндә исә, ул бөтенесенең күз алдында трактирдан чыкты да атын дусларының атлары белән янәшә тәрәзә капкачының бастырыгына бәйләп куйган җирдән чишеп алды, кире кайтканда юлга алдан күз салгаларга кирәклеген коралчыга берничә сүз белән генә аңлатып, аны ышандыргач, аннары, бик игътибар белән тикшергән шикелле, пистолетын карагач, кылычын авызына капты да, үзе теләп бик хәтәр бер эш башкарырга барган солдат кебек, юл буйлап лагерьга таба китте.

## *XV*

## *ИР БЕЛӘН ХАТЫН ОЧРАШУЫ*

Нәкъ Атос уйлаганча, озакламый кардинал аскы катка төшеп тә җитте; мушкетерлар кергән бүлмәнең ишеген ачып карагаңда, Портос белән Арамис бик һәвәсләнеп шакмак уйнап утыралар иде. Кардинал тиз-тиз генә бүлмә эченә күз йөртеп чыкты да бер сакчысы җитешмәгәнлеген күреп:

— Атос әфәнде кая китте? — дип сорады.

— Галиҗәнап, ул алданрак юлны күзәтә китте. Хуҗабызның әйтүеннән Атоста шик туган: юл бигүк куркынычсыз түгел икән,— диде Портос.

— Ә сез нишләдегез соң, Портос әфәнде?

— Менә мин Арамисның биш пистоль акчасын оттым.

— Ярый алайса, хәзер инде минем белән бергә кире кайтыгыз.

— Баш өсте, галиҗәнап хәзрәтләре.

— Шулай итеп, атларыгызга атлана башлагыз, әфәнделәр, вакыт шактый соң инде.

Кардиналның коралчысы, аның атын тезгененнән тотып, ишек төбендә көтеп тора иде. Бераз ерактарак караңгыда ике кеше белән өч ат күренә; болар миледины Ла Пуант фортына чаклы озатып, шунда корабка утыртып җибәрергә тиешле кешеләр иде.

Коралчы кардиналга Атос турында ике мушкетер әйткәннәрнең дөреслеген раслап әйтте. Кардинал «ярый» дип баш кагып кына куйды да, трактирга килгәндәге шикелле барлык саклану чараларын күреп, кайтыр юлга кузгалды.

Ул коралчысы белән ике мушкетер сагында лагерьга таба кайта торсын, без яңадан Атоска әйләнеп кайтыйк.

Атос баштагыча ашыкмыйча гына йөз адым чамасы җир китте дә, үзен беркем карап тормаганлыгын күргәч, уңга борылды, урау юл белән атын юрттырып кире китте һәм, юлдан егерме адым чамасында агачлыкка посып, юлчыларның узып киткәнен көтеп тора башлады. Иптәшләренең киң кырыйлы эшләпәләре һәм кардиналның алтын чачаклы плащы күренгәч, ул җайдакларның юл чатыннан борылып китүләрен көтеп торды да атын кушаяклатып трактирга кайтты. Монда аны тоткарлаучы булмады.

Трактир хуҗасы аны күргәч тә таныды.

— Минем башлык икенче каттагы ханымга бик мөһим бер нәрсәне әйтергә оныткан. Шул ялгышын төзәтү өчен мине җибәрде,— диде Атос.

— Менегез, бүлмәсендә әле ул,— диде хуҗа.

Атос, мондый рөхсәттән файдаланып, баскычка әкренрәк басарга тырышып, өскә менде. Яртылаш ачык ишектән ул милединың эшләпә тасмасын бәйләп торганлыгын күрде.

Атос бүлмәгә килеп керде дә ишекне эчтән бикләп алды.

Миледи, ишек бигенең шылтыраганын ишетеп, борылып карады.

Атос, плащына төренгән, эшләпәсен күзенә үк төшереп кигән килеш, ишек төбендә басып тора бирде.

Таш сын кебек тавыш-тынсыз һәм хәрәкәтсез басып торган бу кешене күреп, миледи курка калды.

— Сез кем? Ни кирәк сезгә? — дип кычкыра төшеп сорады ул.

«Әйе, ул, нәкъ үзе!» — дип уйлады Атос.

Плащын ачып җибәреп, эшләпәсен күтәреп куйды да миледи янына килде.

— Мине таныйсызмы, ханым? — дип сорады.

Миледи алга табарак авышты, аннары кинәт елан күргәндәй артка кайшалды.

— Ярый, яхшы... Күрәм: сез мине таныдыгыз,— диде Атос.

— Граф де ла Фер! — дип пышылдап әйтеп куйды миледи, агарына-агарына, чигенә биреп, стенага барып терәлде.

— Әйе, миледи, граф де ла Фер булам, сезне күреп сөенү өчен юри теге дөньядан кайттым. Кардинал әфәнде әйтмешли, утырышып бер сөйләшик,— диде Атос.

Куркуыннан өнсез калган хәлдә, миледи урындыкка чүгәләде.

— Сез күктән җиргә иңгән явыз рух! — дип сүзгә башлады Атос.— Сезнең хакимлегегез бик зур, мин анысын беләм,

әмма сезгә дә шунысы мәгълүм: кешеләр ходай ярдәме белән еш кына иң явыз рухларны да җиңеп чыкканнар. Сез инде бер тапкыр минем юлымда туры килгән идегез. Мин инде сезне җир йөзеннән юк иткәнмен дип уйлаган идем, ханым, мәгәр я мин ялгышканмын, я сезне җәһәннәм янадан тергезгән...

Бик яман хатирәләрне искә төшергән шушы сүзләр әйтелгәндә миледи, башын аска иеп, әкрен генә аһ-уһ итә башлады.

— Әйе, җәһәннәм янадан терелткән сезне,— дип дәвам итте Атос,— җәһәннәм сезне бай иткән, икенче бер исем биргән сезгә, танып булмаслык диярлек йөзегезне үзгәрткән, ләкин җаныгыздагы пычракны да, тәнегездәге тамганы да юып төшермәгән.

Миледи, пружина атылгандай, сикереп торды, күзләре ялтйолт итә башлады. Атос исә урынында утыра бирде.

— Сез мине үлгән дип уйлагансыздыр, шулаймы? Мин дә сезне үлгән дип уйлаган идем. Ә граф де ла Фер Атос дигән исем астында яшеренеп яшәде, Анна де Бейль миледи Кларик исеме астына яшеренгән кебек! Мөхтәрәм абыегыз безне никахлаган вакытта сезнең исемегез шулай иде түгелме?.. Дөресен әйткәндә, без икебез дә сәер бер хәлдә булып чыктык,— диде Атос авыз чите белән генә көлемсерәп,— без икебез дә бер-беребезне үлгән дип санаганга күрә генә яшәгәнбез: хәтердә саклананнар кайвакыт җанны бик борчыса да, тере җан иясе кебек уңайсызлап тормый бит!

— Сезнең миңа ни йомышыгыз бар? Миннән ни кирәк сезгә? — дип буылган бер тавыш белән сорады миледи.

— Минем сезгә шуны әйтәсем килә: мин, бөтенләй сезгә күренмичә яшәсәм дә, сезне күземнән ычкындырмадым!

— Минем ниләр эшләгәнем сезгә билгелеме?

— Сезнең кардиналга хезмәт итә башлавыгыздан алып, бүгенге кичкә кадәр ниләр эшләгәнегезне көнләп санап чыга алам.

Миледи, ышанмаган төсле, агарынган иреннәрен бөреп елмаеп куйды.

— Тыңлагыз: сез герцог Бекингэмнның кулбашына таккан ике асылташны кисеп алгансыз; Бонасье ханымны урлагансыз; сез де Вардка гашыйк булып һәм аның белән төн уздырырга хыялланып, яныгызга д'Артаньян әфәндене керткәнсез; де Вард сезне алдаган дип белеп, сез аның көндәшеннән де Вардны үтертмәкче булгансыз; аның бу көндәше сезнең хурлыклы серегезне белгәч, аны атып үтерергә дип ике кеше яллап, аның эзеннән җибәргәнсез; аларның пулясы тиешле кешесенә тимәгәнлеген белгәч, сез ялган хат язып, аңа агулы шәраб җибәргәнсез, хәтта ул шәрабны дусларыгызның бүләге дип, корбаныгызны алдамакчы булгансыз; һәм, иң соңгысы, менә биредә, шушы бүлмәдә, менә хәзер мин утырган шушы урындыкка утырып, әле яңарак кына кардинал Ришелье каршында герцог Бекингэмны үтертәм дип өстегезгә йөкләмә алдыгыз, моның

бәрабәренә ул сезгә д'Артаньянны үтерергә рөхсәт итәм дип сүз бирде.

Милединың йөзе үлек чырае төсле агарынып китте.

— Сез үзегез иблис! — дип пышылдап кына әйтеп куйды ул.

— Ихтимал, шулайдыр, әмма һәрхәлдә бер нәрсәне белеп торыгыз: сез герцог Бекингэмны, үзегез үтерәсезме, я булмаса, башка бер кешедән үтертәсезме,— минем анда эшем юк: ул кешене мин белмим, өстәвенә ул инглиз дә, әмма д'Артаньянның бер бөртек чәченә дә кагыласы булмагыз: ул минем турылыклы дустым, мин аны яратам һәм саклап киләм, югыйсә, мәрхүм атам исеме белән ант итеп әйтәм, әгәр шул җинаятьне эшли калсагыз, иң соңгы җинаятегез булыр ул!

— Д'Артаньян мине бик яман мәсхәрә итте, д'Артаньян үләчәк,— диде миледи тонык бер тавыш белән.

— Чынлыкта сезне мәсхәрә итү мөмкинмени, ханым? — диде Атос көлеп.— Ул сезне мәсхәрә итте һәм ул үләчәкмени?

— Үләчәк,— диде миледи кабатлап.— Башта сөяркәсе, аннары үзе.

Атосның күз аллары караңгыланып китте. Үзендә берниндн хатын-кыз сыйфаты калмаган бу адәмнең кыяфәте Атосның күңелендә җанга авыр хатирәләрне тергезеп җибәрде. Бервакыт, хәзергедән куркынычсызрак бер хәлдә, Атос, үз намусын саклап, бу хатынны юк итәргә теләгәнен хәтерләде; менә хәзер тагын аны үтерәсе килү теләге йөрәгеп ут кебек кызыштырып кабынды да бөтен барлыгын биләп алды. Атос урыныннан торып, биленә кыстырган пистолетын тартып алды да чакмасын күтәрде.

Үлек чырае төсле агарынган миледи кычкырмакчы булып авызын ачты, ләкин теле әйләнмәде, һәм аның катып калган авызыннан кеше сөйләшенә охшаудан бигрәк ерткыч ырылдавына тартым гыжылдаган бер аваз гына чыкты; караңгы стенага сөялгән, чәч-башлары тузгып таралган хәлдә, ул коточкыч куркыныч бер нәрсәгә әйләнгән иде.

Атос экрен генә пистолетын күтәреп, көпшәсе милединың маңгаена тия язарлык итеп кулын сузды да тагы да котны алырлык тәвәккәл, тыныч тавыш белән өзеп әйтте:

— Ханым, я сез кардинал кул куйган теге кәгазьне шушы минутта ук чыгарып миңа бирәсез, я, җаным белән ант итеп әйтәм, маңгаегызга пуля җибәрәм.

Бу урында башка бер кеше булса, миледи аның бу ниятен эшли алуына ышанып та җитмәс иде, ләкин Атосның кемлеген ул бик яхшы белә иде; шулай да миледи кузгалмыйча-селкенмичә тик тора бирде.

— Уйларга бер секунд вакыт бирәм,— диде Атос.

Аның йөзе җыерылуын күреп, миледи менә хәзер Атосның атып җибәрәчәген төшенде. Кулын тиз генә түшенә китереп, изү эченнән кәгазьне алды да Атоска бирде.

— Мәгез, ләгънәт төшсен сезгә! — диде.

Атос кәгазьне алып, пистолетын бил каешына кыстырды да, бу — шул кәгазь микән дип карау өчен, лампа янынарак барды һәм кәгазьне ачып, мондый сүзләрне укыды:

«Моны күрсәтүче кешенең кылган гамәле минем боерык буенча һәм дәүләт файдасы өчен эшләнде.

3 нче декабрь, 1627 ел.

*Ришелье».*

Атос плащына төренә-төренә, эшләпәсен киеп:

— Менә хәзер, тешләреңне суырып алгач, тешли алсаң, тешләп кара инде, зәһәр елан! — диде дә бүлмәдән чыгып китте, артына әйләнеп тә карамады.

Трактир ишеге төбендә ул ике атлы җайдакны күрде, алар тагын бер атны тезгененнән тотып торалар иде.

— Әфәнделәр,— диде аларга Атос,— үзегезгә мәгълүм булганча, кардинал җәнаплары, вакытны әрәм итмичә, теге хатынны Ла Пуант фортына илтергә һәм ул корабка утырмыйча аны ташлап китмәскә кушты.

Атосның әйткәне бу кешеләр үзләре алган боерыкка бик туры килгәнлектән, алар боерыкны үтәргә әзер икәнлекләрен белгертеп башларын гына иделәр.

Атосның үзенә килгәндә исә, ул ялт кына сикереп ияренә атланды да атын җан-фәрманга чаптырып китеп барды, тик ул юл буйлап китмәде, атын бик каты шпорлый-шпорлый туп-туры кыр аркылы гына җилдерде, ара-тирә туктап, тыңлаштыргалап та алды.

Әнә шулай бер туктавында юлда ат аяклары тавышы ишетте. Атос, боларны тәгаен кардинал белән аның сакчылары икәнен белеп, тагын бераз алгарак узды да, атын арчан ботаклары һәм яфраклар белән сөрткәләгәч, лагерьга ике йөз адым чамасы кала юлга чыкты.

Атлы җайдакларны әйбәтләбрәк күргәч инде:

— Кемнәр бу? — дип кычкырды.

— Бу безнең батыр мушкетер булса кирәк? — дип сорады кардинал.

— Әйе галиҗәнап, нәкъ шул үзе,— дип җавап бирде Атос.

— Атос әфәнде, безне яхшы саклаганыгыз өчен минем рәхмәтемне кабул итегез. Менә кайтып та җиттек, әфәнделәр. Сез сул заставага барыгыз, пароль: «Король һәм Ре».

Шулай дигәч, кардинал баш кагып кына өч дусты белән саубуллашты да, коралчысын ияртеп, уңга борылды,— ул лагерьда гына куныл калырга ниятли иде.

Кардинал китеп, боларны ишетә алмаслык булгач, Портос белән Арамис бертавыштан:

— Менә шулай, кардинал миледи таләп иткән язуны язып, кул куеп бирде,— дип сүз башладылар.

— Беләм. Менә ул кәгазь,— диде Атос тыныч кына.

Сакчыларга парольне әйтүләрен исәпләмәгәндә, өч дус, квартирларына кайтып җиткәнче, ләм-мим сүз сөйләшмәделәр.

Мәгәр, кайтып җиткәч, Мушкетонны Планше янына, хуҗаң траншеядагы каравылдан бушау белән үк мушкетерлар квартирына килеп җитсен, дип әйтергә җибәрделәр.

Миледига килгәндә исә, ул, нәкъ Атос уйлаганча, трактир ишеге төбендә үзен көтеп торучы кешеләрне күргәч, бернинди каршылыксыз аларга иярде. Шулай да кыска гына бер арада аңарда кире кайтып, кардинал янына барырга да бөтенесен сөйләп бирергә дигән теләк тә уянып алды, ләкин ул Атосны фаш итсә, Атос та аны фаш итәр иде: әйтик, миледи кайчандыр үзен Атос асып киткәнлеген әйтте ди, ул чагында Атос аның хурлык тамгасы белән тамгаланган булуын әйтәчәк. Шуңа күрә миледи бу хакта эндәшмичә, яшерен рәвештә китеп, өстенә алган авыр эшне үзенә хас үткенлек-чаялык белән башкарып чыгу, аннары инде, шуларның барысын эшләп кардиналны сөендергәннән соң, аның янына кайтып, ханымга үзе өчен үч кайтарырга ярдәм итүен сорау яхшырак булыр дип уйлады.

Шулай итеп, миледи, төн буе ат өстендә барып, иртәнге сәгать җидедә Ла Пуант фортына килеп җитте, сәгать сигездә инде корабка утырды, ә сәгать тугызда кардинал кул куйган каперлык* таныклыгы белән тәэмин ителгән һәм, янәсе, Байонага китәргә әзер булып торган кораб якорен күтәрде дә Англия ярларына таба юл тотты.

## XVI

## СЕН-ЖЕРВЕ БАСТИОНЫ

Д'Артаньян дуслары янына килеп кергәндә алар барысы бер бүлмәдә иде: Атос үзенең ниндидер уйларына бирелгән, Портос мыегын бөтергәләп утыра; Арамис бик матур зәңгәр тышлы кечерәк бер догалык буенча гыйбадәт кылып тора иде.

— Шайтан алгыры, әфәнделәр! — диде д'Артаньян.— Сезнең миңа бик мөһим бер нәрсә әйтәсегез бардыр дип беләм, югыйсә, кисәтеп куям, бүгенге төнне бастион яулап алып, шуны җимергәннән соң мине ял иттермичә монда китергәнегез өчен гафу итмәм. Аһ, сезнең шунда булмавыгыз бик кызганыч, әфәнделәр! Гаять кызу булды анда эшләр!

— Ә без икенче бер җиргә барып эләктек, анда да салкын булмады,— диде Портос, мыек очларын җилле генә бөтереп.

— Тсс! — дип куйды Атос.

Д'Артаньян, мушкетерның ни өчен каш җыерганын аңлап алып:

---

* Диңгездә дошманның сәүдә корабларын тоту.

— Оһо! Сездә берәр яңалык бар, ахры? — диде.
— Арамис, сез өченче көн теге «Мөртәт»тә, калвинистлар мәйханәсендә ашагансыз бугай? — дип сорады Атос.
— Әйе.
— Ничек соң анда?
— Начар ашадым мин: ураза көн иде, итсез ашлар гына ашаттылар.
— Ничек инде ул алай? Диңгез гаване була торып, балык та юкмыни? — диде Атос, гаҗәпләнеп.
— Кардинал җәнаплары өйдерә торган дамба бөтен балыкны ачык диңгезгә качыра, диләр.— Арамис шулай дип аңлатып бирде дә яңадан гыйбадәтенә керешге.
— Мин сездән ул хакта сорамаган идем, Арамис! Үзегезне анда иркен хис кылдыгызмы, борчучы-нитүче булмадымы? — дип соравым иде.
— Ул кадәр бәйләнчек кешеләр күп түгел бугай анда... Әйе, чыннан да, Атос, сез сөйлисе сүз өчен «Мөртәт» бик кулай урын булыр безгә.
— Алайса «Мөртәт»кә киттек, монда стеналар кәгазь кебек юка бит,— диде Атос.
Дустының гадәт-кыланышларын инде белеп-иялэшеп беткән д'Артаньян аның бер сүзе, бер кул хәрәкәте яки ишарәсеннән үк хәлнең җитди икәнлеген шундук төшенеп, Атосны култыклап алды да, бүтән берни сорашмыйча, аның белән бергә чыгып китте. Портос белән Арамис та, дусларча гәпләшә-гәпләшә, алар артыннан иярделәр.
Юлда аларга Гримо очрады. Атос аңа ымлап кына үзләренә ияреп барырга кушты; Гримо, гадәтенчә, ләм-мим сүз эндәшмәстән, хуҗа әфәндесе кушканга риза булды: ул бичара сөйләшүен онытып бара иде бугай инде.
Дуслар мәйханәгә килеп җиттеләр. Иртәнге сәгать җиделәр тирәсе булып, яктыра башлаган чак иде. Хуҗага аш-су китерергә кушып, залга керделәр. Хуҗаның әйтүенә караганда, монда аларны беркем дә борчымаска тиеш иде.
Кызганычка каршы, сер сөйләшер өчен вакыты җайлы булып чыкмады: әле яңа гына иртәнге чаңны суктылар, һәм күп кеше, йокыларыннан айну һәм иртәнге чык салкыныннан җылыныр өчен, узышлый гына мәйханәгә берәр стакан шәраб эчәргә сугылгалый башлады. Бер-бер артлы драгуннар, швейцарлылар, гвардиячеләр, мушкетерлар һәм кавалеристлар кереп-чыгып тора, анысы хуҗа өчен бик файдалы булса да, дүрт дусның исәбенә бөтенләй туры килми иде. Шуңа күрә алар сугышчан дусларының сәламенә, тост һәм шаяртуларына да кашларын җыерып кына җавап кайтардылар.
— Җитәр, әфәнделәр! — диде Атос.— Болай безнең монда берәрсе белән талашып китүебез дә ихтимал, ә хәзергә алай итү бер дә кирәк түгел безгә. Д'Артаньян, бу төнне ничек үткәргәнегезне сөйләгез әле, без үзебезнекен соңыннан сөйләрбез.

Кулындагы бер рюмка аракысын ашыкмыйча тәмләп кенә эчә-эчә, бераз чайкалгалап торган бер кавалерист сүзгә кушылды:

— Чыннан да, чыннан да, гвардияче әфәнделәр, сез бүген төнлә траншеяларда булдыгыз бит, ларошельлеләр белән исәп-хисапны өздегез бугай?

Д'Артаньян, сүз арасына килеп кысылган бу адәмгә җавап бирергәме-юкмы дигән сыман, Атоска карады.

— Де Бюзиньи әфәнденең сиңа хөрмәт күрсәтеп мөрәҗәгать иткәнен ишетмисеңмени? — диде Атос.— Бу әфәнделәр хәлнең ничек булганын белергә теләгәч, бүген төнләниләр булганын сөйләп бир инде алайса.

— Сез пастионны алтыкысмы? — дип сорады сыра кружкасыннан ром эчеп торган бер швейцарлы.

— Әйе, әфәндем, безнең өлешкә тиде андый бәхет,— дип җавап бирде д'Артаньян, башын иеп.— Без хәтта бастионның бер чатына бер мичкә дары да куйдык,— бәлки, сез аны ишеткәнсездер дә,— дары шартлап, ярыйсы ук тишек хасил булды, калган стеналары да какшады — бастион яңа түгел бит инде, иске.

Кылычына каз түшкәсе кадап шуны тотып торган бер драгун (ул аны кыздырырга дип алып килгән иде):

— Ә кайсы бастион ул? — дип сорады.

— Сен-Жерве бастионы. Ларошельлеләр, шуңа ышыкланып, безнең җир казучыларны борчып торалар иде,— дип җавап бирде д'Артаньян.

— Бик каты булдымы эшләр?

— Каты булды шул! Безнең биш кеше үлеп калды, ларошельлеләрнең тугызмы-унмы кешесе.

— Шайтан алкыры! — дип куйды швейцарлы, немец телендә бик шәп сүгенү сүзләре булса да, французча сүгенергә гадәтләнеп киткән иде ул.

— Алар инде бастионны төзәтү өчен бүген җир казучылар командасы җибәрми калмаслардыр?

— Ихтимал,— дип җөпләп куйды д'Артаньян.

— Әфәнделәр, пари тәкъдим итәм! — диде Атос.

— Әһә, пари! — дип куәтләп җибәрде швейцарлы.

— Нинди пари? — дип сорады кавалерист.

— Туктап торыгыз әле,— дип үтенде драгун, кылычын шеш тимере шикелле итеп ут янып торган ике зур тимер таган өстенә куйды,— мин дә катнашырга телим. Әй, пешмәгән трактирчы, тиз генә калай таба куегыз монда, бу кадерле казның бер тамчы мае да әрәм булмасын!

— Төрес әйтә: кас мае фаренье белән пик тәмле,— диде швейцарлы.

— Менә шулай! — дип җиңел сулап куйды драгун.— Ә хәзер безнең парига күчәбез. Тыңлыйбыз сезне, Атос әфәнде!

— Әйе шул, нинди пари ул? — дип сорады кавалерист.

— Алайса шул, де Бюзиньи әфәнде, мин сезнең белән шул хакта пари тотам,— дип сүзгә кереште Атос,— өч дустым — Портос, Арамис, д'Артаньян әфәнделәр — һәм мин, Сен-Жерве бастионында иртәнге ашны ашап, дошман безне бастионнан бәреп чыгарырга никадәр тырышса да, шунда минутына хәтле төгәл бер сәгать торачакбыз.

Портос белән Арамис күзгә-күз карашып алдылар: эшнең хикмәтенә төшенә башладылар алар.

— Шәфкатьсез булма, безне үтерәчәкләр бит анда! — дип пышылдады д'Артаньян Атосның колагына.

— Анда бармасак, безне үтерүләре тагы да тәгаенрәк,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Валлаһи, бик шәп пари бит бу, әфәнделәр! — диде Портос, урындык аркасына сөялеп киерелебрәк утырды да мыек очларын бөтереп җибәрде.

— Әйе, мин дә кабул итәм моны. Хакы турында гына килешәсе калды,— диде де Бюзиньи.

— Әфәнделәр, сез дә дүртәү, без дә дүртәү. Сигез кешелек аш мәҗлесе, кем нинди аш тели. Ни диярсез сез шуңа? — диде Атос.

— Искиткеч! — диде де Бюзиньи.

— Бик шәп! — дип җөпләде драгун.

— Риза! — диде швейцарлы да.

Бу тамашага сүзсез генә катнашучы дүртенче кеше дә ризалыгын белдереп баш какты.

— Ашыгыз әзер, әфәнделәр,— дип килеп әйтте хуҗа.

— Әзер булса, китерегез! — диде Атос.

Трактир хуҗасы кушканга шундук күнде. Атос Гримоны чакырып алды да залның бер почмагында торган зур гына кәрзингә ымлады һәм салфеткага кыздырган ит төргән сыман итеп куллары белән бөтереп күрсәтте.

Гримо сүзнең табигать кочагында ашап-эчеп утыру турында икәнлеген бик тиз төшенеп, кәрзинне барып алды да шуңа ашамлыклар тутырды, алар янына шешәләр дә куйды һәм шуннан соң кәрзинне беләгенә асты.

— Сез кайда ашарга җыенасыз? — дип сорады трактир хуҗасы.

— Аш-суыгызның хакын түләгәч, сезнең өчен барыбер түгел мени? — диде Атос.

Һәм мәһабәт бер төс белән өстәлгә ике пистоль акча ташлады.

— Сдачасын кайтарып биримме, офицер әфәнде? — дип сорады хуҗа.

— Кирәкми. Ике шешә шампань шәрабы гына өстә дә, калганы салфеткалар өчен булыр.

Трактирчынын, башта уйлаганча, болар белән эше бик үк табышлы булып чыкмады, шулай да кимен куймады ул: басти-

онга барып ашап утырырга җыенган дүрт дуска шампань шәрабы урынына анжуй шәрабы тоттырып җибәрде.

— Де Бюзиньи әфәнде, сез сәгатегезне минекенә карап дөреслисезме, әллә мин сезнекенә карап дөреслимме? — диде Атос.

— Бик яхшы, галиҗәнап! — диде кавалерист, кесәсеннән асылташлар белән зиннәтләгән бик шәп сәгатен чыгарды.— Сигезенче ярты.

— Сигезенче утыз биш минут,— диде Атос.— Искәреп куйыйк: минем сәгать сезнекеннән биш минутка алдарак, галиҗәнап.

Шаккатып калган трактир халкына баш ия-ия, дүрт егет Сен-Жерве бастионына таба юл тоттылар, аларга беләгенә кәрзин аскан Гримо ияргән, егет үзенең кая барганын да белми,— ул инде Атос кушканга берсүзсез буйсынырга күнегеп беткән, сорарга кирәклеге башына да килми иде.

Дүрт дус лагерь эченнән барганда бер сүз сөйләшмәделәр; өстәвенә, аларның пари тотуын ишетеп, артларыннан байтак кына «ачык авыз» да ияргән, безнең дүрт дусның әлеге хәлдән ничек котылуларын күрергә телиләр иде. Ләкин лагерь ныгытмалары сызыгын узып, кыр уртасына килеп чыккач, моңарчы берни белми барган д'Артаньян төшендереп-аңлатып бирүләрен сорарга вакыт дип уйлады.

— Хәзер инде, Атос дус, үтенәм сездән: әйтегез әле — без кая барабыз? — дип сүзгә керешге ул.

— Күреп торасыз ич: бастионга барабыз,— диде Атос.

— Анда нишлибез инде?

— Белгәнегезчә, без анда барып ашап утырачакбыз.

— Ә нигә без «Мөртәт»тә генә ашамадык соң?

— Чөнки бик кирәкле сүз сөйләшәсебез бар, ә бу мәйханәдә биш минут та иркенләп сөйләшеп утырып булмый: гел кеше кереп-чыгып тора, иелеп-сыгылып исәнләшкән булалар, сүз кушалар. Монда, ичмасам, берәү дә килеп комачауламаячак безгә,— диде Атос, бастионга таба күрсәтеп.

— Минемчә, без диңгез буенда, дюналар арасында да берәр аулак урын таба алган булыр идек...— диде д'Артаньян, гайярьлеге белән бик табигый яраша торган саклыгын күрсәтеп.

— ...Һәм анңары безнең дүртәү сөйләшеп утырганны бөтен кеше күрер иде дә бер унбиш минуттан кардиналның шымчылары, безне киңәш корып утыралар иде дип, аңа җиткерерләр иде.

— Шулай, Атосның әйткәне хак: «Animadvertuntur in desertis» *,— диде Арамис.

— Чүлгә чыгу начар булмас иде дә, аны табуы кыен шул,— дип куйды Портос.

---

* Аларны чүлдә күрәләр (*латинча*).

— Баш өстеннән кош очып үтмәстәй, су өстенә балык калыкмастай, оясыннан куян килеп чыкмастай чүл юк ул. Миңа калса, кош та, балык та, куян да — барысы да инде кардиналның шымчысы булып беткәннәр. Шуңа күрә безгә башлаган эшебезне дәвам иттерүдән дә яхшысы булмас; хәер, хур булыйк димәсәк, без бу эштән кире чигенә дә алмыйбыз. Без пари тоттык, аны хәйлә белән эшләнгән дип әйтә алмыйлар һәм аның чын сәбәбен бирәү дә белмәячәк дип ышанам мин. Парины оту өчен без бастионда бер сәгать торабыз. Я безгә һөҗүм итәчәкләр, я андый хәл булмаячак. Әгәр безгә һөҗүм итмәсәләр, сөйләшергә вакытыбыз җитәрлек булачак, һәм безне беркем тыңлап та тормаячак: бу бастион стеналарының колагы юк дип тәгаен әйтә алам. Әгәр безгә һөҗүм итсәләр дә, эшләребез хакында сөйләшеп өлгерә алабыз, өстәвенә дошманга каршы торып, дан-шөһрәт тә казанабыз. Менә үзегез күрәсез: кайсы якка гына борсаң да, гел безнең файдага килеп чыга.

— Шулаен шулай да, тик барыбер пулядан котылып кала алмыйбыз,— диде д'Артаньян.

— Әй дустым, иң куркыныч пуляның дошман җибәргән пуля түгеллеген бик яхшы беләсез бит,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Шулай да, минемчә, мондый сәяхәткә чыкканда, һич югы, мушкетларыбызны алырга кирәк иде,— диде Портос сүзгә кушылып.

— Акылсыз икәнсез, Портос дус: нигә алай кирәкмәгән йөк күтәреп йөрергә!

— Дошман белән кара-каршы килгәндә төзек мушкет, бер дюжина патрон һәм бер савыт дары бер дә артык әйбер булып тоелмый миңа.

— Д'Артаньянның ни дигәнен ишетмәдегезмени сез?

— Ни диде соң ул?

— Төнге атака вакытында тугыз-ун француз һәм шул чаклы ук Ларошель кешесе үлеп калды, диде.

— Я, шуннан?

— Аларның коралларын алып өлгермәгәннәрдер әле, шулаймы? Ул вакытта бөтенесенең дә эшләре бик ашыгыч булгандыр.

— Я, шуннан ни була?

— Шуннан шул була: аларның мушкет, дары, патроннарын без алабыз, һәм дүрт мушкет белән бер дюжина пуля урынына безнең унбишләп мылтыгыбыз, запаста йөзләп пулябыз була.

— Ай, Атос, чыннан да, бөек кеше икәнсең син! — дип куйды Арамис.

Портос та бу фикер белән килешкәнлеген белдереп баш иде.

Атосның бу дәлилләре бер д'Артаньянны гына ышандырып җиткерә алмады шикелле.

Егетнең бу шик-шөбһәләрен Гримо да уртаклаша иде, күрәсең: баштарак бастионга баруларына ышанмаган Гримо, чыннан да шулай икәнен күргәч, хуҗа әфәндесенең чабуыннан тартты да: «Кая барабыз?» — дигән мәгънәдә ишарә ясады.

Атос бастионга таба төртеп күрсәтте.

Сүзсез-өнсез Гримо шул ук ишарә телендә: «Безне анда үтерәләр бит»,— дигәнне аңлатты.

Атос күккә таба күзен төбәп, кулларын күтәрде.

Гримо кәрзинне җиргә куйды да бармыйм дип башын чайкый-чайкый җиргә утырды.

Атос биленнән пистолетын алып, әйбәт корылганмы дип караштыргалады һәм, чакмасын күтәреп, пистолет көпшәсен Гримоның колак төбенә китереп терәде.

Гримо шундук — ялт! — сикереп тә торды.

Атос аңа ымлап кына кәрзинне күтәреп алдан барырга кушты.

Гримоның инде буйсынмый хәле булмады.

Аның бу бер-ике минутлык ишарәле әңгәмәдән откан бердәнбер нәрсәсе шул булды — хезмәтче егет арьергардтан авангардка күчте.

Дүрт дус, бастион өстенә менгәч, артка әйләнеп карадылар.

Лагерь заставасы янына барлык гаскәри төрдән өч йөзләп солдат җыелган, алардан чак кына бер читтәрәк басып торган де Бюзиньи әфәндене, драгунны, швейцарлыны һәм парига сүзсез-өнсез генә катнашкан дүртенче кешене дә танып булырлык иде.

Атос эшләпәсен башыннан салып, кылычы очына элде дә һавага күтәреп болгады.

Тамаша кылып торучылар аның сәламенә каршы баш иеп җавап кайтардылар, каты итеп «ура» кычкырулары безнең дүрт батырга да килеп ишетелде.

Шуннан соң дүрт дус бастион эченә кереп киттеләр, ә Гримо анда алданрак шылган иде.

## XVII

## МУШКЕТЕРЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Хәл, чыннан да, Атос уйлаганча булып чыкты: бастионда уникеләп француз һәм Ларошель кешеләре мәетләреннән башка бернинди адәм заты да юк иде.

Сәяхәткә башлык итү эшен үз өстенә алган Атос болай диде:

— Әфәнделәр, Гримо табын әзерли торган арада без эшне мылтык һәм патроннар җыюдан башлыйк. Өстәвенә, шуларны җыйган чакта иркенләп сөйләшә дә алабыз: бу әфәнделәр безне ишетмәсләр,— диде ул үлеләргә ишарәләп.

— Аларны чокырга гына ташлау яхшырак булмасмы? — диде Портос.— Әлбәттә, кесәләрен тентеп, әйберләре юклыгына ышанганнан соң дим.

— Әйе, анысы инде Гримо эше,— дип куйды Атос.

— Алайса Гримо аларны тентеп чыксын да стена аша гына ыргытсын,— диде д'Артаньян.

— Алай итү һич ярамый. Безгә аларның кирәк булып куюы ихтимал,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Бу мәетләрнең безгә кирәк булуы ихтимал? — диде Портос сәерсенеп.— Әллә акылыңнан яздыңмы, дускай?!

— «Алай ашык-пошык кына хөкем чыгармагыз»,— дип әйтә изге китап та, кардинал җәнаплары да,— диде Атос.— Ничә мылтык булды, әфәнделәр?

— Унике,— диде Арамис.

— Запаста ничә пуля?

— Йөзгә якын.

— Безгә шул җиткән. Мылтыкларны корып куябыз!

Шулай дип, дүрт дус эшкә керештеләр.

Соңгы мылтыкны корып бетергәндә Гримо ишарәләп-ымлап кына табын әзер икәнлеген хәбәр итте.

Атос «яхшы!» дигән кебек кул селекте дә каравыл манарасын күрсәтте, Гримоның аңлавынча, ул шунда сакта торырга тиеш иде.

Сакта торган чагында күңелсез булмасын өчен Атос аңа ипи, ике котлет һәм бер шешә шәраб алырга рөхсәт итте.

— Хәзер инде табынга утырышыйк! — диде Атос дусларын чакырып.

Дүрт дус, төрекләр яки тегүчеләр шикелле, аяк бөкләп, җиргә утырдылар.

— Хәзер инде тыңлап-ишетеп тормагайлары дип куркырлык сәбәп юк, шулай булгач, син безгә серенне сөйләп бирерсең дип өметләнәм,— диде д'Артаньян.

— Әфәнделәр, монда килүебезнең ләззәте дә, дан-шөһрәте дә булмый калмас дип уйлыйм мин,— дип сүзгә кереште Атос.— Мин сезне гаҗәеп бер сәйранга чыгардым. Менә сезгә тәмле ризык, ә-әнә тегендә,— бойница тишекләреннән карасагыз, үзегез дә күрерсез,— безне биш йөзләп кеше тамаша кылып тора, бу ике төр ахмакларның беришесе безне акылдан шашкан дип, икенчеләре герой дип саный.

— Ә теге сер? — диде д'Артаньян.

— Сер дигәнем шул: кичә кич миледины күрдем мин,— дип җавап кайтарды Атос.

Ул шушы сүзне әйткәндә д'Артаньянның кулындагы стаканын нәкъ авызына таба күтәргән чагы иде, миледи дигәнне ишетүгә, кулы дер-дер калтырана башлады да, шәраб түгелмәсен дип, ул стаканны кире җиргә куеп торырга мәҗбүр булды.

— Син үзеңнең ниеңне...

— Тсс! — диде Атос, аны бүлдереп.— Сез, дустым, бу әфәнделәрнең минем гаилә хәлләре белән таныш түгеллеген онытып җибәрәсез. Шулай итеп, миледины күрдем мин кичә.

— Кайда күрдегез? — дип сорады д'Артаньян.

— Моннан ике лье чамасында, «Күгәрчен оясы» кунакханәсендә.

— Алайса минем баш бетте,— дип куйды д'Артаньян.

— Юк әле, бөтенләй үк бетеп җитмәгән, чөнки миледи хәзер Франция ярларыннан ерак китеп баргандыр,— диде Атос, аның бу сүзенә каршы.

Д'Артаньян җиңел сулап куйды.

— Һаман миледи да миледи дисез, кем соң ул миледи? — дип сорады Портос.

Атос:

— Бик чибәр бер хатын,— диде дә күбекләнеп торган шәрабын бераз эчеп куйды.— Нәләт төшкән трактирчы! — дип кычкырып куйды ул аннары.— Шампань шәрабы урынына анжуй шәрабы тоттырып җибәргән бит, безне алдадым ди торгандыр ул!.. Әйе, бик чибәр бер хатын,— дип әлеге сүзенә әйләнеп кайтты,— шул миледи безнең дустыбыз д'Артаньянга шактый җылы караш күрсәткән булган да дустыбыз аңа нииндидер бер этлек эшләп киткән, шуннан соң инде миледи аңардан үч алырга маташа: моннан бер ай элек аны үтерергә кешеләр яллаган, бер атна элек агулап үтермәкче булган, ә менә кичә кардиналдан дустыбызның башын бетерергә фатиха сорады.

Д'Артаньян, куркуыннан агарынып китеп, кычкырып җибәрде:

— Ничек инде?! Минем башны бетерергә кардиналдан фатиха сорады?

— Хак сүз, мин үз колагым белән ишеттем,— диде Портос.

— Мин дә ишеттем,— диде Арамис та.

— Алайса көрәшеп маташуның файдасы юк инде. Ичмасам, үз маңгаема үзем пуля җибәрәм дә шуның белән эшне бетерәм,— дип сөйләнеп куйды д'Артаньян, өметсезлеккә төшеп.

— Андый ахмаклыкны эшләргә кайчан да өлгерерсең, ул эшне кире төзәтеп булмый бит,— диде Атос.

— Шундый көчле дошманнарым барында барыбер яшәмәячәкмен мин,— диде д'Артаньян Атосның бу сүзенә каршы.— Беренчедән, Мёңгта очраган ят кеше, аннары де Вард — анысына өч тапкыр кылыч белән кададым, аннары миледи — анысының очраклы рәвештә яшерен бер серен ачтым, һәм, ниһаять, кардинал — анысына үч алырга комачауладым.

— Һи, күпмени ул? Дүртәү генә ич! — диде Атос.— Без дә дүртәү бит. Димәк, бергә — бер булып чыга... Шайтан алгырысы! Гримоның ишарәләвенә караганда, хәзер безгә тагы да күбрәк дошман белән эш итәргә туры киләчәк... Нәрсә бар, Гримо? Хәлнең бик җитди булуын искә алып, мин сезгә сөйлә-

шергә рөхсәт итәм, тик, зинһар, кыскарак тотыгыз. Ниләр күрәсез сез анда?

— Отряд.

— Ничә кеше?

— Егерме.

— Кемнәр алар?

— Уналты кеше җир казу командасыннан, аннары дүрт солдат.

— Моннан ничә адымда?

— Биш йөз.

— Яхшы, без әле тавыкны ашап, синең исәнлеккә берәр стакан шәраб эчәргә өлгерәбез, д'Артаньян!

Портос белән Арамис та:

— Синең исәнлеккә! — дип куәтләп җибәрделәр.

— Ярый алайса, минем исәнлеккә булсын! Шулай да сезнең бу яхшы теләкләрегез миңа әллә ни зур файда китерер дип уйламыйм.

— Күңелеңне төшермә!— диде Атос.— Мөхәммәт өммәтендәгеләр әйтмешли, алланың кодрәте киңдер, ул ни кылса, шул булыр.

Атос шәрабын эчеп бетереп, стаканын үзе янына җиргә куйды да әкрен генә урыныннан торды, беренче туры килгән мылтыкны алып, бойница янына китте.

Портос, Арамис һәм д'Артаньян да шулай иттеләр, ә Гримо дүрт дусның артына басып, мылтыкларны корып торырга дигән боерык алды.

Беравыктан отрядның килгәне дә күренде. Бастион белән кала арасында багланыш юлы хезмәтен үтәгән тар гына траншея буйлап килә иде ул.

— Шайтаным! Кәйлә, көрәк белән генә коралланган ике дистә кала кешесе өчен мәшәкатьләнеп торырга кирәк иде микән безгә?! — диде Атос.— Монда килмәгез дип Гримоның бер ишарә ясавы да җитәр иде һәм шуннан соң, тәгаен, безне борчып та йөрмәсләр иде.

— Ай-һай, алай булыр микән. Безгә таба бик батыр атлый болар. Өстәвенә, кала кешеләрен мушкет белән коралланган бригадир һәм дүрт солдат та озата килә,— диде д'Артаньян.

— Алар әле безне күрмәгәнгә генә батыраеп киләләр,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Ихластыр, ант әгәр, бу бичара кала кешеләренә мылтык төзәп атарга кулым бармый минем,— дип куйды Арамис.

— Диннән язганнарны кызганган изге ата изге ата түгел инде ул! — диде Портос.

— Чыннан да, Арамис дөрес әйтә. Хәзер мин барып кисәтәм аларны,— диде Атос.

— Нинди шайтан котыртты сезне! Кая барасыз! Атып үтерәләр бит үзегезне, дустым! — дип, д'Артаньян аны туктатып калмакчы булды.

Мәгәр Атос бу сүзне колагына да элмәде, бастион стенасындагы зур гына тишеккә менеп басты да, бер кулына мылтыгын, икенчесенә эшләпәсен тоткан килеш, көтмәгәндә генә аның пәйда булуына гаҗәпләнеп, бастионнан илле адым чамасында туктап калган солдатлар белән җир казучыларны баш иеп сәламли-сәламли, болай дип кычкырды:

— Әфәнделәр, хәзер мин берничә дустым белән шушы бастионда мәҗлес корып утырам! Ашап-эчеп утырган вакытта читтән килеп борчысалар, кәефнең бозылганын үзегез дә беләсездер. Шуңа күрә, әгәр инде сезнең монда бик киләсегез килсә, без ашап-эчеп туйганчы сабыр итүегезне яисә соңыннан тагын бер тапкыр килүегезне сорыйбыз... Я булмаса, иң яхшысы — акылыгызга килеп, фетнәчеләрне ташлагыз да безнең янга Франция короле исәнлегенә шәраб эчәргә рәхим итегез.

Д'Артаньян:

— Саклан, Атос! Сиңа мушкетларын төзиләр бит — күрмисеңмени? — дип кычкырды.

— Күрәм, күрәм, бу кала кешеләре бик начар аталар алар, миңа тидерә алмыйлар,— дип җавап кайтарды Атос.

Чыннан да, шул минутта ук дүрт тапкыр мушкеттан атканнары ишетелде, ләкин пулялары, Атоска тимичә, аның тирәсендәге ташларга эләгеп яньчелде.

Моңа җавап итеп бу яктан да дүрт мушкет шартлады, тик бу мушкетлар һөҗүм итүчеләрнекенә караганда чосрак төзәлгән булып чыкты. Өч солдат шундук җиргә авып җан бирде, җир казучыларның берсе яраланды.

— Гримо, икенче мушкетны бир! — дип кычкырды Атос, стена тишегеннән төшмичә генә.

Гримо шундук кушканны үтәде. Атосның өч дусты яңадан мылтыкларын кордылар. Беренче залп артыннан икенчесе кабатланды: бригадир белән ике җир казучы шунда егылып үлеп калды, башкалары исә кире борылып кача башладылар.

— Алга, әфәнделәр, куа чыгабыз! — дип команда бирде Атос.

Дүрт дус тиз генә йорт эченнән чыктылар да сугыш мәйданына йөгереп барып, дүрт мушкет белән бригадирның сөңгесен алдылар һәм качып китүчеләрнең калага кайтып җитмичә туктамаячакларын белеп, трофейлары белән бастионга кире кайттылар.

— Гримо, мылтыкларны корып куегыз,— дип боерды Атос.— Ә без хәзер, әфәнделәр, яңадан табынга утырышып, әңгәмәбезне дәвам иттерик. Кай җирдә тукталып калган идек әле?

— Мин бик яхшы хәтерлим: миледи, Франция ярларын калдырып, китеп барды, дигән идең,— диде д'Артаньян. «Кая юл тотты икән ул миледи?» — дип бик нык борчуга төшкән иде егет.

— Англиягә китте ул,— диде Атос.

— Нинди максат белән икән?

— Бекингэмны үзе үтерү яки кеше яллап үтертү максаты белән.

Бу сүзне ишеткәч, д'Артаньян гаҗәпләнүеннән һәм нәфрәтеннән «аһ!» итеп куйды. Кычкыра төшеп:

— Нинди түбәнлек! — диде.

— Анысы өчен мин тамчы да кайгырмыйм! — дип кенә куйды Атос.— Гримо, хәзер инде, мылтыкларны корып бетергәч, бригадир сөңгесен алыгыз да шуңа салфетка бәйләп, безнең бастионның манарасы өстенә кадап куегыз: ул фетнәче Ларошель кешеләре үзләренең батыр һәм турылыклы король солдатлары белән эш иткәнлекләрен күреп-белеп торсыннар.

Гримо кушканны берсүзсез үтәргә кереште. Беравыктан инде безнең дүрт дусның баш өстендә ак әләм җилфердәп тора башлады. Манара өстендә әләм күренү белән артта шаулатып кул чаптылар: лагерь халкының яртысы вал өстенә җыелган иде.

— Ничек инде ул алай? — дип, д'Артаньян яңадан сүзгә кереште.— Милединың Бекингэмны үзе үтерүе, я булмаса кеше яллап үтертүе сине бер дә борчымыймыни? Герцог — безнең дус ич ул!

— Герцог ул — инглиз, герцог безгә каршы сугыша. Миңа димәгәе, миледи герцогны теләсә ни эшләтсен, минем өчен ул ни дә менә шушы буш шешә ни — икесе бер.

Шулай дигәч, Атос әле генә соңгы тамчысына хәтле шәрабыннан бушаган шешәне аргы почмакка ук ыргытып җибәрде.

— Юк, туктале,— диде д'Артаньян,— Бекингэмны алай язмыш кулына ташлап калдыра алмыйм мин! Бер дигән яхшы атлар бүләк итте бит ул безгә.

— Бигрәк тә, бер дигән иярләр бүләк итте әле,— дип сүз кыстырды Портос, бу минутта аның плащында ияреннән алып теккән бик матур ука елкылдап тора иде.

— Өстәвенә ходай гөнаһлы бәндәнең үлүен түгел, бәлки иманга килүен тели,— диде Арамис бу сүзне куәтләп.

— Амин,—дип куйды Атос.— Бик теләсәгез, бу сүзгә соңыннан кайтып сөйләшербез. Ә ул вакытта мине иң борчыган нәрсә - - син мине аңларсың дип ышанам, д'Артаньян — мине иң борчыган нәрсә — әлеге хатынның кардиналдан теләнеп алган рөхсәт кәгазен кулга төшерү иде. Шул кәгазь ярдәмендә ул сине ансат кына юк итмәкче иде, сине генә түгел, ихтимал, безнең барыбызны да юк итәргә җыенган булгандыр әле.

Портос, кыздырган ит тураган Арамиска таба тәлинкәсен сузып:

— Әллә иблис затыннанмы ул хатын?! — диде, ачуы килеп.

— Ә ул рөхсәт кәгазе аңарда калдымы? — дип сорады д'Артаньян.

— Юк, ул кәгазь минем кулга күчте, шулай да мин аны ансат кына кулга төшердем димәс идем.

— Атос дустым,— диде д'Артаньян ихлас күңеле белән,—

син мине күпме тапкыр үлемнән коткарып калдың — мин инде моның исәбен дә оныттым!

— Син шулай миледи янына керер өчен безне калдырып киткән идеңмени? — дип сорады Арамис.

— Әйе, нәкъ шуның өчен.

— Кардинал язып биргән ул кәгазь хәзер синдәме инде? — дип төпченүендә булды д'Артаньян.

Атос:

— Менә ул кәгазь,— дип, плащ кесәсеннән әлеге кадерле кәгазьне чыгарып бирде.

Д'Артаньян, калтырануын яшерергә тырышмастан, куллары дерелди-дерелди, кәгазьне ачты да мондый сүзләрне укыды:

«Бу кәгазьне күрсәтүченең кылган гамәле минем боерык буенча һәм дәүләт файдасы өчен эшләнде.

3 декабрь, 1627 ел.

*Ришелье».*

— Чыннан да, бөтен кагыйдәсен китереп гөнаһларны кичерү икән шул бу,— диде Арамис.

— Бу кәгазьне ертып ташларга кирәк,— дип сөйләнеп куйды д'Артаньян, менә әле генә үзенә карата чыгарылган үлем карарын укыган кебек хис кылды ул үзен.

— Юк, киресенчә, күз карасы кебек сакларга кирәк моны. Әллә ничаклы алтын бирсәләр дә, бу кәгазьне кулдан ычкындырмыйм мин,— диде Атос дустының әлеге сүзенә каршы.

— Ә хәзер миледи нишләр икән соң? — дип сорады яшь егет.

— Кардиналга зарланып хат язардыр, күрәсең,— диде Атос исе китмәгән бер төс белән.— Атос исемле нәләт төшкере бер мушкетер рөхсәт кәгаземне талап алды, дияр. Кардиналга шул мушкетерның ике дусты Портос белән Арамистан да арынырга киңәш итәр. Кардинал инде боларның һәрвакыт үз юлында очрый торган кешеләр икәнлеген исенә төшерер һәм көннәрдән бер көнне д'Артаньянны кулга алырга кушар, ә аның ялгызына күңелсез булмасын өчен, аңа иптәшкә безне дә Бастилиягә озаттырыр.

— Бик шомлы нәрсәләргә ишарәләп шаярта башладың әле, дустым,— диде Портос.

— Бер дә шаяртмыйм,— диде Атос бу сүзгә каршы.

— Ә син беләсең бит, ул каһәр суккыры милединың муенын борып ташлауның гөнаһысы бичара һугенотларны үтерүдән азрак. Һугенотларның бөтен җинаяте бары шул гына: без латинча җырлый торган догаларны алар французча җырлыйлар.

— Бу турыда безнең аббат нәрсә дияр икән соң? — дип куйды Атос тыныч кына.

— Нәрсә әйтим: Портосның фикере белән килешәм,— диде Арамис.

— Мине инде әйтәсе дә юк! — диде д'Артаньян.

— Бәхеткә каршы, миледи хәзер ерак киткән шул инде,— диде Портос.— Ихластыр, монда булса, мине бик уңайсызлар иде ул.

— Англиядә булса да, Франциядәге шикелле үк уңайсызлый ул мине,— диде Атос.

— Ә мине бөтен җирдә уңайсызлый,— диде д'Артаньян.

— Кулыңа бер килеп эләккәч, нигә син аны суга батырып, я буып яки асып үтермәдең? — диде Портос.— Үлгәннәр кире әйләнеп кайтмыйлар бит.

— Шулай дип уйлыйсызмы, Портос? — диде Атос шомланган бер төс белән елмаеп. Моның мәгънәсен бер д'Артаньян гына аңлый иде шул.

— Минем башка бик шәп бер фикер килде! — диде д'Артаньян.

— Я, әйтегез,— диделәр мушкетерлар.

— Кора-ал! — дип кычкырды шул чакны Гримо.

Егетләр сикерешеп тордылар да кулларына коралларын алдылар.

Бу юлы егерме-егерме биш кешелек чамасы кечерәк бер отряд килә, әмма болары инде җир казучылар түгел, гарнизон солдатлары иде.

— Лагерьга кайтып китмикме? Минемчә, көчләр тигез түгел бит,— диде Портос.

— Алай итеп булмауның өч сәбәбе бар,— диде Атос.— Беренчедән, без әле ашап-эчеп туймадык; икенчедән, безнең бик кирәкле нәрсәләр хакында сөйләшәсебез бар; өченче сәбәбе шул: тиешле вакытына хәтле тагын ун минут бар әле.

— Шулай да сугышуның планын төзергә кирәк,— диде Арамис.

— Аның планы бик гади,— диде Атос.— Дошман мылтыктан атарлык арага җитү белән без ут ачабыз; килүеннән туктамаса, тагын атабыз һәм мылтыкларны корырлык дары белән ядрә калганчы шул рәвешчә дәвам иттерәбез. Исән калганнары өскә басып килә башласа, без аларга чокырга төшәргә ирек бирәбез дә стенаның чак-чак кына убылмыйча эләгеп торган өлешен өсләренә ишеп төшерәбез.

— Браво! — дип кычкырып куйды Портос.— Син чыннан да полководец булыр өчен тугансың, Атос; кардинал үзе турында сугыш эшенең даһие дип уйласа да, синең янда чүп кенә ул.

— Әфәнделәр, зинһар, бер кешегә икәү атмагыз; һәркем мылтыгын үзенең дошманына гына төзәсен,— диде Атос, дусларын искәртеп.

— Мин үземнекен мушкага алдым,— диде д'Артаньян.

— Мин дә алдым,— диде Портос.

— Мин дә,— диде Арамис.

— Атарга! — дип команда бирде Атос.

Дүрт мылтык тавышы бергә кушылып гөрс итүгә, дүрт солдат җиргә ауды.

Шуның артыннан ук отряд, барабан кагып, йөгерә-атлый һөҗүмгә килә башлады.

Бу яктан, мылтыкларын чос төзәп, гөрс-гөрс атарга тотындылар. Әмма Ларошель кешеләре, безнең дусларның аз булуын белеп горган кебек, хәзер инде таралышып, һаман килә бирделәр.

Өч атуга тагын ике кешеләре егылып калды, ләкин шуңа да карамастан, исәннәре һаман алга баруларында дәвам иттеләр.

Бастион янына уникеме-унбишме кеше килеп җитте; боларны соңгы залп белән каршы алдылар, ләкин бу ату да һөҗүмчеләрне туктата алмады: алар чокыр эченә сикереп төшеп, стена тишегеннән керергә җыена башладылар.

— Ягез әле, дуслар, бер сугуда юк итик әле үзләрен. Стенага! Стенага! — диде Атос.

Дүрт дус һәм аларга булышучы Гримо стенаның зур бер өлешен мылтык көпшәләре белән этеп урыныннан кузгатырга керештеләр. Стена җилдә чайкалган шикелле янтая башлап, нигезеннән купты да гөрселдәп чокырга ауды. Җан ачысы белән ачыргаланып кычкырган тавышлар ишетелде, күккә таба бөркелеп тузан болыты күтәрелде, һәм шуның белән дошманның эше дә бетте.

— Әллә берсен-бер калдырмый сытып бетердекме? — дип сорады Атос.

— Әйе шул, шайтан алгырысы, бөтенесен бетердек бугай,— диде д'Артаньян.

— Юк, әнә икәүме-өчәүме качып баралар, бөтенләй имгәнгәннәр үзләре,— диде Портос бу сүзгә каршы.

Чыннан да, ишелгән стена астына эләгүчеләрнең өчесеме-дүртесеме, канга һәм тузанга батып, канау юлы буйлап калага таба качып китеп баралар. Монда җибәрелгән отрядтан бары шулар гына исән калган иде.

Атос сәгатенә күз салды да:

— Әфәнделәр, безнең монда килгәнебезгә нәкъ бер сәгать булды димәк, хәзер без парины оттык. Ләкин уенчы булсаң, бер дигәне булырга кирәк, өстәвенә д'Артаньян безгә үзенең фикерен дә әйтеп өлгермәде бит әле,— диде.

Шулай дигәч, мушкетер, гадәтенчә ашыкмыйча, сабыр гына табынга барып утырды.

— Минем фикеремме? — дип кайтарып сорады д'Артаньян.

— Әйе, башка бик шәп бер фикер килде дигән идегез,— диде Атос.

— Ә, әйе, искә төште: мин яңадан Англиягә барып, Бекингәмны күрәм.

— Сез алай итмисез, д'Артаньян,— диде Атос салкын гына.

— Нигә? Минем анда бер тапкыр булганым бар бит инде.

— Барын бар да, ул вакытта ике арада сугыш юк иде шул, Бекингэм да безнең дошманыбыз түгел, союзнигыбыз иде. Сезнең ул ниятегезне ватанга хыянәт итү дип санаячаклар.

Д'Артаньян, бу дәлилнең бик нигезле икәнлеген аңлап, эндәшмәде.

— Минем башка да әйбәт кенә бер фикер килде шикелле,— дип куйды Портос.

— Я, тыңлап карыйк, Портос нәрсә уйлап тапты икән! — диде Арамис.

— Мин, берәр сылтау тапкан булып, де Тревиль җәнапларыннан ял сорыйм,— сылтавын сез уйлап табарсыз, минем андый эшкә осталык юк. Миледи мине белми, шуңа күрә мин, берниндн шик-мазар тудырмыйча, аның янына бара алам. Мин ул чибәрне эзләп табам да буып үтерәм.

— Ярый, тагын аз гына җитеп бетмәгәне дә өстәлсә, мин Портосның тәкъдимен кабул итәргә риза,— диде Атос.

— Фи, хатын-кыз үтерү! — дип каршы төште Арамис.— Юк, минә фикернең иң дөресе минем башка килде ул.

— Башыгызга нинди фикер килде, Арамис, әйтегез! — диде Атос, бу мушкетер егеткә бик зур хөрмәт белән карый иде ул.

— Королеваны искәртеп куярга кирәк.

— Әйе шул, чыннан да! — диделәр Портос белән д'Артаньян. Аннары соңгысы болай дип өстәде:

— Минемчә, дөрес әмәлен таптык без.

— Королеваны искәртеп куярга! — диде Атос кабатлап.— Ә ничек эшләргә соң аны? Безнең король сарае белән бәйләныш бармы соң? Парижга берәр кеше җибәрсәк, шундук бөтен лагерьга билгеле булмас дисезме? Моннан Парижга чаклы йөз кырык лье ара. Хатыбыз Анжерга да барып җитмәс — үзебезне тотып төрмәгә утыртырлар!

— Хатны ничек итеп ышанычлы юл белән королевага тапшыру мәсьәләсенә килгәндә,— дип кызарынып сүзгә башлады Арамис,— анысын мин үз өстемә алам. Турдан бик үткен бер ханымны беләм мин...

Арамис, Атосның елмаюын күреп, сүзеннән туктап калды.

— Менә сиңа кирәк булса! Сез бу тәкъдимгә каршымыни, Атос? — диде д'Артаньян гаҗәпләнеп.

— Мин аны бөтенләй үк кире какмыйм,— диде Атос,— тик Арамиска шуны гына әйтәсем килә: ул бит лагерьны ташлап китә алмый, ә үзебездән башка беркемгә дә ул эшне ышанып тапшырып булмый: безнең йомышчы китеп, ике сәгать үтү белән үк кардиналның бөтен иярченнәре, шымчылары, бөтен ялчылары сезнең хатыгызны яттан беләчәкләр, аннары инде сезне дә, сезнең үткен ханымыгызны да кулга алачаклар.

— Королева Бекингэмны коткарса да, безне коткармаячагын әйтеп торасы да юк инде,— дип куйды Портос.

— Әфәнделәр, Портосның әйткәнендә хаклык юк түгел,— диде д'Артаньян.

— Оһо! Нинди тамаша куркан ул калада? — дип сорады Атос.

— Тревога кагалар.

Дуслар тавышка колак салдылар; чыннан да калада барабан кагулары ишетелде.

— Менә күрерсез: безгә каршы бер полк кеше җибәрерләр,— диде Атос.

— Шул бер полкка каршы торырга җыенмыйсыздыр бит? — дип сорады Портос.

— Ә нигә каршы тормаска? — диде мушкетер.— Минем хәзер иң кызган чак, әгәр безнең тагын бер дюжина шешә шәраб булса, полкка гына түгел, армиягә дә каршы торыр идем.

— Валлаһи, барабан тавышы якыная бара,— диде д'Артаньян, дусларын искәртеп.

— Якынайсын,— диде Атос.— Моннан калага чаклы чирек сәгатьлек юл. Шулай булгач, каладан монда хәтле чирек сәгать килергә кирәк әле. Бер-бер карарга килү өчен ул кадәр вакыт безгә бик җиткән. Әгәр без моннан китсәк, сөйләшер өчен мондый җайлы урынны беркайдан да таба алмаячакбыз. Аннан ары, беләсезме, әфәнделәр, минем башка нәкъ менә хәзер фикернең иң асылы килә.

— Әйтегез алайса!

— Иң элек Гримога тиешле боерыкларымны бирергә рөхсәт итегез.

Атос кулын изәп кенә хезмәтчесен дәшеп алды да, бастионда яткан мәетләргә таба күрсәтеп, боерыгын әйтте:

— Гримо, әнә ул галиҗәнапларны торгызып, стенага сөягез дә башларына эшләпәләрен кигезеп, кулларына мушкетлар тоттырыгыз.

— О даһи! Аңлыйм мин сине,— дип куйды д'Артаньян.

— Сез аңлыйсызмыни? — дип кайтарып сорады Портос.

— Ә сез аңлыйсызмы, Гримо? — диде Арамис.

Гримо «әйе» дип баш какты.

— Эшлисе эш менә шул,— диде Атос.— Хәзер инде минем фикергә әйләнеп кайтыйк.

— Шулай да моның мәгънәсен бик беләсем килә минем,— дип үзенекен куәтләде Портос.

— Аны белүнең кирәге юк.

— Әйе шул, Атосны тыңлыйк әле! — диделәр д'Артаньян белән Арамис.

— Шул милединың, шул хатынның, шул кабахәт затның, шул иблиснең кайнагасы бар икән, сез шулай дип әйткән идегез шикелле, д'Артаньян...

— Әйе, мин аны күреп тә беләм, минемчә, ул киленен бик үк яратып бетерми бугай.

— Анысы начар түгел, ул аны дошман курсә, тагы да яхшырак булыр иде,— диде Атос.

— Ул чагында шартлар безнең теләккә бик туры килә.

— Шулай да Гримоның ни эшләгәнен бик беләсем килә минем,— дип үз сүзен кабатлады Портос.

— Көеп торыгыз әле, Портос! — диде Арамис, аны сүзеннән тыеп.

— Кайнагасы ни исемле?

— Лорд Винтер.

— Хәзер кайда ул?

— Сугыш башлана дигән хәбәрләр таралу белән Лондонга кайтып китте.

— Безгә нәкъ шундый кеше кирәк тә,— диде Атос.— Менә аны искәртеп куярга кирәк. Без аңа килешнәренең кемнедер үтерергә җыенуын белгертербез дә ул хатынны күздән ычкындырмавын үтенербез. Лондонда изге Магдалина приюты яисә тәүбә иткән бозык хатыннар йорты шикелле берәр төрле тәрбия йорты бардыр дип беләм. Лорд Винтер киленнәрен шунда яптырыр да аннары без тынычланып калырбыз.

— Әйе, миледи аннан чыкканчы,— диде д'Артаньян килешеп.

— Валлаһи, сез артык күп таләп итәсез, д'Артаньян,— диде Атос.— Мин булган кадәр фикеремне әйтеп бетердем. Запаста башка бер фикерем дә юк, белеп торыгыз.

Арамис та үз фикерен әйтте:

— Ә минемчә, королева белән лорд Винтерны икесен дә искәртеп куйсак, тагы да яхшырак булыр.

— Анысы шулай да, ә менә Турга һәм Лондонга хатларны кем аркылы җибәрәбез соң?

— Мин бу эшне Базенга ышанып тапшыра алам,— диде Арамис.

— Ә мин Планшега,— диде д'Артаньян.

Портос та сүзгә кушылды:

— Чыннан да, без үзебез лагерьны ташлап китә алмасак та, хезмәтчеләребезгә тыелмый бит.

— Бик дөрес,— диде Арамис.— Бүген үк хат язып, куллырына акча бирәбез дә юлга чыгарып җибәрәбез.

— Акча бирәбез? — дип кайтарып сорады Атос.— Бездә акча бармыни?

Дүрт дус күзгә-күз караштылар да ачылып киткән чырайлары янадан караңгыланды.

— Карагыз әле! — дип кычкырып җибәрде д'Артаньян.— Кара һәм кызыл төрткеләр күрәм... әнә киләләр. Сез полк дигән идегез, Атос! Полк кына түгел, армия бит бу!

— Әйе, сүзегез хак, киләләр шул! — диде Атос.— Ошыймы сезгә ул хәйләкәрләр? Барабан какмыйча, быргы кычкыртмыйча тып-тын гына киләләр... Әй, эшләп бетердеңме инде, Гримо?

— Гримо бетергәнлеген белгертеп баш какты да уникe мәеткә таба төртеп күрсәтте — аларны ул стена буена килешләрен бик китереп бастырып куйган: беришеләре мылтыкларын җилкәләренә күтәреп басып тора, икенчеләре мылтыкла-

рын төзәгән, өченчеләре исә кулларына ялангач кылыч тоткан иде.

— Браво! Менә монысы инде синең осталыгыңны күрсәтә! — диде Атос аның эшен хуплап.

— Шулай да моның мәгънәсен бик беләсем килә минем,— дип, Портос яңадан теге сүзен башлады.

— Башта без моннан тайыйк, шуннан соң мәгънәсен аңларсың,— диде аңа д'Артаньян.

— Сабыр итегез әле, әфәнделәр, сабыр итегез бераз. Гримо табынны җыеп алсын инде.

Шул вакыт Арамис кычкырып җибәрде:

— Оһо! Кара һәм кызыл төрткеләр күзгә күренеп зураялар, шуңа күрә мин дә д'Артаньян фикеренә кушылам: минемчә, безгә монда вакыт уздырып торасы юк, тизрәк лагерьга кайтып китәргә кирәк.

— Әйе, хәзер инде чигенергә мин дә каршы түгел,— диде Атос.— Без бер сәгатькә дип пари тоткан идек, ә монда сәгать ярым булдык. Хәзер инде безгә беркем бәйләнә алмый. Киттек, әфәнделәр, киттек.

Гримо, кәрзинен һәм калган азыкларны күтәреп, алга чыгып йөгерә үк башлаган иде инде.

Дүрт дус аның артыннан бастионнан чыктылар һәм, бер ун адым атлагач, Атос кинәт әйтә куйды:

— Их, шайтан алгыры, нишләвебез бу безнең, әфәнделәр?! — диде.

— Әллә берәр нәрсәңне онытып калдырдыңмы? — дип сорады д'Артаньян.

— Байрагыбыз кала бит, шайтан алгыры! Гади бер салфетка гына булса да, байракны дошманга калдырырга ярамый бит.

Шулай дип, Атос бастионга кире йөгерде дә манарага менеп, байракны алды. Бу вакытта инде ларошельлеләр мылтыктан атарлык арага килеп җиткәнлектән, кызык өчен ядрә астына барып кергән сыман тоелган бу кешегә төбәп, утергеч ут ачтылар.

Ләкин Атос тылсымлаган кебек иде: пулялар аның тирәсеннән генә сызгырып уза, берсе дә аңа тими иде.

Атос кала саклаучыларга арты белән борылды да лагерь саклаучыларны сәламләп байрак болгады. Ике яктан да каты итеп кычкырган авазлар ишетелде: бер яктан — ачу-ярсу белән, икенче яктан сокланып кычкыралар иде.

Беренче залп артыннан икенчесе гөрселдәде, һәм өч пуля салфетканы тишеп чын байракка әйләндерде.

Бөтен лагерь:

— Төшегез, төшегез! — дип кычкырды.

Атос аска төште; борчылып көтеп торган иптәшләре шатланышып каршы алдылар аны.

— Киттек, Атос, киттек, кызурак атлыйк, кызурак! — дип ашыктырды д'Артаньян.— Хәзер инде, акча табудан башка,

бөтенесен уйлап хәл иткәч, монда үлеп калу ахмаклык булыр иде.

Шулай да Атос, иптәшләренең үгетләвенә карамастан, мәһабәт бер кыяфәт белән ашыкмый гына атлый бирде, иптәшләре дә, үгетләп маташуның файдасыз икәнен күреп, аның җаена атладылар.

Гримо белән аның кәрзине болардан шактый алда, дошман пулясы җитмәслек арада иде инде.

Беравыктан котырып мылтык аткан тавышлар ишетелде.

— Бу ни дигән сүз? Кемгә аталар алар? — диде Портос гаҗәпләнеп.— Мин аларга каршы пулялар сызгырганын да ишетмим, беркемне күрмим дә.

— Алар безнең теге мәетләргә аталар,— диде Атос.

— Әмма мәетләр аларга каршы атмыйлар ич!

— Нәкъ шулай. Шуннан алар, безгә засада оештырганнар, дип уйлыйлар да киңәшә башлыйлар, парламентер җибәрәләр, аннары инде эшнең хикмәтен төшенеп алгач, соң була, безгә тидерә алмыйлар. Шуңа күрә безгә хәзер кату чыгарып ашыгасы юк.

— Әһә, төшендем! — диде Портос исе китеп.

— Ярый, аллага шөкер! Төшенсәң бик шәп! — дип куйды Атос, җилкәсен сикертеп.

Французлар, дүрт дусның ашыкмый гына кайтып килүләрен күргәч, хәйран калып кычкыра-шаулаша башладылар.

Тагын шарт-шорт мылтык атулары ишетелде, бу юлы инде пулялар безнең дуслар тирәсендә юл буендагы ташларга тиеп яньчелә, вышт-вышт итеп колак төпләреннән сызгырып үтә башлады. Ларошельлеләр, ниһаять, бастионны яулап алдылар.

— Бөтенләй ата белмиләр икән! — диде Атос.— Без аларның ничә кешесен атып үтердек әле? Уникесенме?

— Унбиш булмаса.

— Ә күпмесен сыттык?

— Сигезнеме, унныймы.

— Ә моның бәрабәренә безнең бер җиребез тырналмады да! Юк, шулай да... Кулыгыз нишләде, д'Артаньян? Әллә каныймы?

— Бернәрсә дә юк,— диде д'Артаньян.

— Адашкан пуля тидеме әллә?

— Пуля да түгел.

— Нәрсә соң алайса?

Атосның д'Артаньянны улы урынына күреп яратканлыгын бер тапкыр әйткән идек инде; караңгы чырайлы, кырыс күңелле бу кеше вакыт-вакыт егеткә саф аталарча кайгыртучанлык күрсәтә иде.

— Тырналды гына,— диде д'Артаньян.— Бармакларым стена ташына кысылды да йөзек ташы тиресен уйды.

— Асылташлы йөзек киеп йөрү менә нишләтә бит ул, галиҗәнап! — диде Атос көлгән сыман бер тон белән.

— Ә, әйе шул, чыннан да йөзеге асылташлы бит әле! — дип

кычкыра төшеп әйтеп куйды Портос.— Шайтаным, нәрсәгә без акча юк дип зарланабыз соң әле?

— Шулай шул! — диде Арамис та аны җөпләп.

— Браво, Портос! Бу юлы чыннан да бик шәп фикер килде башыңа!

— Әлбәттә,— диде Портос, Атосның мактавына масаеп китеп,— асылташ булгач, аны сатарга да мөмкин бит.

— Королеваның бүләге ич ул,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Алай булгач, бигрәк тә эшкә кушарга ярый аны,— диде Атос.— Королева бүләгенең сөйгәне Бекингэмны коткаруы бик гадел эш, безне, королеваның дусларын, коткаруы исә бер яхшылык булыр, шуңа күрә асылташны сатабыз да җибәрәбез. Аббат җәнаплары ни уйлый соң бу хакта? Мин инде Портосның фикерен сорап тормыйм, аныкы мәгълүм.

— Минемчә, бу йөзекне сөйгән яры бирмәгән икән, димәк ки, мәхәббәт билгесе түгел икән, ул чагында д'Артаньян аны сата да ала,— диде Арамис кызарынып.

— Дустым, адәм кыяфәтенә кергән изге китап кебек сөйлисез сез. Димәк, сезнең фикерегезчә...

— Асылташны сатарга кирәк,— дип җавап бирде Арамис.

— Яхшы алайса! Асылташны сатарбыз, бу турыда бүтән сөйләшмик,— диде д'Артаньян ризалашып.

Арттан һаман аталар иде әле, тик инде безнең дуслар шактый ара китеп өлгергәннәр, аларга мылтыктан атып тидерерлек түгел, ларошельлеләр җан тынычлыгы өчен генә аталар иде.

— Чынлап, бу матур фикер Портосның башына бик вакытлы килде бит әле: менә без кайтып та җиттек. Шулай итеп, әфәнделәр, әлеге эшләр хакында бүтән бер сүз дә сөйләшмибез. Әнә безгә карап торалар, безгә каршы киләләр һәм хәзер безне тантана белән каршы алачаклар.

Чыннан да, алда әйткәнебезчә, бөтен лагерь урыныннан купкан иде: ике меңнән артык кеше, сәхнә тамашасы караган шикелле, дүрт дусның исән-сау килеш зур каһарманлык күрсәтеп кайтып килүләрен карап тора; монда баруларының төп сәбәбен, билгеле, беркем белми иде.

Лагерь өстендә алкышлау авазлары айкала:

— Яшәсен гвардиячеләр! Яшәсен мушкетерлар! — дип кычкыралар.

Иң беренче кеше булып Бюзиньи әфәнде килеп Атосның кулын кысты да: парины оттыгыз, диде. Бюзиньидан соң драгун белән швейцарлы килде, болар артыннан инде калган барлык иптәшләре йөгерешеп килделәр. Тәбрикләү-котлау, кул кысу, кочаклау, шаярып һәм Ларошель кешеләреннән көлеп әйткән сүзләрнең иге-чиге булмады. Шундый зур тавыш, шау-гөр купты — кардинал хәтта, берәр фетнә чыкканмы әллә дип, үз гвардиясенең капитаны Ла Удиньерны лагерьда ни барлыгын белешергә җибәрде.

Кардиналның йомышчысы лагерьга килгәч, булган хәлне, егетләрнең батырлыгына исләре китеп, сөйләп бирделәр. Ла Удиньер әйләнеп кайткач:

— Я, нәрсә бар? — дип сорады кардинал.

— Галиҗәнап, өч мушкетер белән бер гвардияче егет, Сен-Жерве бастионына барып, табын корып ашап-эчеп утырабыз дип де Бюзиньи әфәнде белән пари тоткан булганнар һәм шунда ике сәгать буе табын ясап, дошманга бирешмичә, ларошельлеләрнең бик күп кешеләрен кырып кайтканнар.

— Сез ул өч мушкетерның исемнәрен белмәдегезме?

— Белдем, галиҗәнап.

— Әйтегез әле.

— Атос, Портос һәм Арамис әфәнделәр алар.

«Һаман да шул өч батыр!» — дип куйды кардинал эченнән генә.

— Ә гвардиячесе?

— *Анысы* — д'Артаньян әфәнде.

— Һаман шул хәйләкәр малай! Бу дүрт дус миңа хезмәткә күчәргә тиеш.

Кичен кардинал, де Тревиль әфәнде белән сөйләшеп утырган чагында, бөтен лагерьның исен китәргән әлеге каһарманлыкны да телгә алды. Де Тревиль әфәнде бу маҗара хакында егетләрнең үз авызыннан ишеткән иде, шуңа күрә аны кардинал хәзрәтләренә җентекләп сөйләп бирде, хәтта салфетканы әләм итеп манара өстенә кадап куюларын да онытмады.

— Бик шәп бит бу, де Тревиль әфәнде! — диде кардинал.— Шул салфетканы миңа җибәртегез әле, мин аңа өч алтын лалә чиктереп, мушкетерларыгызга штандарт итеп тапшырырмын.

— Галиҗәнап, алай итү гвардиячеләрне рәнҗетү булмасмы соң? Д'Артаньян миндә түгел, Дезэссар кул астында бит,— диде де Тревиль бу сүзгә каршы.

— Алайса сез аны үзегезгә алыгыз,— диде кардинал.— Бу дүрт батыр егет, бер-берләрен бик яраткач, бергә хезмәт итсеннәр.

Де Тревиль әфәнде бу күңелле хәбәрне шул кичтә үк өч мушкетер белән д'Артаньянга җиткерде һәм шунда дүртесен дә иртәгә үзенә иртәнге ашка чакырды.

Д'Артаньянның шатлыгы эченә сыймады. Белгәнебезчә, аның тормышындагы иң зур хыялы мушкетер булу иде бит.

Өч дусты да моңа бик сөенделәр.

— Валлаһи, синең башка искиткеч шәп фикер килгән һәм син хаклы да булып чыктың,— диде д'Артаньян Атоска,— без анда барып шөһрәт казандык һәм үзебез өчен бик кирәкле әңгәмәне башлап җибәрдек...

— ...Һәм хәзер без, беркемдә шик уятмыйча, ул әңгәмәне дәвам иттерә дә алабыз: моннан ары без, ходайның ярдәме белән, кардиналчылар дигән исем күтәреп йөриячәкбез бит.

Д'Артаньян шул кичне үк Дезэссар әфәндегә үзенең ихтира-

мын белгертү һәм кардинал кылган яхшылыкны әйтү өчен аның янына китте.

Дезэссар әфәнде д'Артаньянны бик ярата иде, шуңа күрә, әлеге яңалыкны белгәч, ярдәм күрсәтергә теләвен әйтте: бер полктан икенчесенә күчүнең гаскәри кирәк-ярак һәм кием юнәтү дигән зур гына чыгымнары бар иде.

Д'Артаньян аның ярдәменнән баш тартты, шулай да, бу уңайдан файдаланып, асылташка бәя куюын үтенде һәм, аны акчага әйләндерүен сорап, йөзекне аңа бирде.

Икенче көнне иртәнге сәгать сигездә д'Артаньян янына Дезэссарның лакее килеп, егеткә бер янчык алтын тапшырды, янчыкта җиде мең ливр акча бар иде.

Королева биргән асылташның бәһасе шулай иде.

## *XVIII*

## *ГАИЛӘ ЭШЕ*

Атос гаилә эше дигән бик кулай бер сүз тапты. Гаилә эше кардиналның карамагына керми; гаилә эше беркемгә кагылмый; гаилә эше белән бөтен кеше күз алдында шөгыльләнергә мөмкин иде.

Шулай итеп, Атос гаилә эше дигән сүз тапты.

Арамис исә шул эш белән хезмәтчеләрне җибәрү хәйләсен уйлап тапты.

Ә Портос асылташны сату чарасын тапты.

Тик бер д'Артаньян гына, дүртесе арасында иң зирәге булса да, берни уйлап таба алмады, дөресен әйткәндә, милединың исеме генә дә бөтенләй аның уйлау сәләтен бетергән иде.

Әй, алай ук түгел, ялгышканбыз икән: асылташны сатып алырдай кеше тапты бит ул.

Де Тревиль әфәнде оештырган аш мәҗлесе бик кәефле, күңелле узды. Бирегә инде д'Артаньян яңа киемнәрен киеп килде: буйга ул Арамис белән бер чамадарак иде, ә Арамис,— укучыларым хәтерли торгандыр: аның поэмасын сатып алган нәшир акчаны бик юмарт биргән иде,— бөтен кирәк-яракны икешәрдән алган иде, шуңа күрә бер комплект киемен дустына бирде.

Д'Артаньянның күңел күзе алдында офыктагы кара болыт шикелле миледи калкып тормаса, егет җиде кат күкләрдә гизәр иде.

Бу аш мәҗлесеннән соң дуслар кич белән Атос янына җыелып, уйлаган эшләрен шунда сөйләшеп бетерергә сүз куештылар.

Д'Артаньян, өр-яңа мушкетер киеменнән, көн буе лагерь урамнарында йөрде.

Кичен, сөйләшенгән вакытта, дүрт дус бергә җыелдылар; өч нәрсәне хәл итәселәре бар иде:

милединың кайнагасына хат язу,

Турдагы үткен-чая ханымга хат язу,

хатны илтеп тапшыру өчен хезмәтчеләрнең кайсысын җибәрү.

Дусларның һәркайсы үз хезмәтчесен тәкъдим итте: Атос Гримоның бик тыйнак булуына басым ясап әйтте: хуҗа әфәндесе аңа авызын ачарга рөхсәт итсә генә сөйләшә икән ул; Портос Мушкетонның көчле булуын мактады: Мушкетон гәүдәгә шундый таза — гадәти кешеләрнең дүртесен берьюлы тукмап ташлый ала икән. Базенның чаялыгына ышанган Арамис та үз кандидатын тетеп мактады; Планшеның батырлыгына һичбер шиге булмаган д'Артаньян исә аның Булоньдагы четерекле хәл вакытында үзен тотышын мактап сөйләде.

Шушы дүрт яхшы сыйфат бер-берсе белән шактый озак ярыштылар, аларны яклап бик оста итеп нотыклар да әйтелде, без аларын, артык озын тоелыр дип, монда язып тормыйбыз инде.

— Бәхетсезлеккә каршы, безнең йомышчыбызда ул дүрт сыйфатның дүртесе дә юк шул,— дип куйды Атос.

— Каян аласың андый хезмәтчене?

— Үзем дә беләм: андыйны табып булмый,— диде Атос килешеп.— Шуңа күрә Гримоны алыгыз.

— Юк, Мушкетонны.

— Базеннан да яхшысы юк инде.

— Ә минемчә, Планше яхшы. Ул батыр да, чая да: менә әлеге дүрт сыйфатның икесе бар инде.

— Әфәнделәр,— дип сүзгә кереште Арамис,— безнең өчен белергә кирәкле төп нәрсә дүрт хезмәтчебезнең кайсысы тыйнаграк, көчлерәк, чаярак һәм батыррак булуы түгел бит; иң төп нәрсә — кайсысының күбрәк акча яратуы.

— Шактый акыллы фикер бу,— диде Атос,— кешеләрнең яхшы сыйфатына түгел, начар сыйфатына исәп тотарга кирәк. Сез бөек үгет-нәсихәтче икәнсез, аббат хәзрәтләре!

— Әлбәттә, төп нәрсә шул,— дип сүзендә дәвам итте Арамис.— Кушкан йомышыбызны ышанычлы итеп башкарып чыгардай кешеләр уңышка ирешү өчен генә түгел, бәлки уңышсызлыкка очрамас өчен дә кирәк безгә. Уңышсызлыкка очраган тәкъдирдә башы белән җавап бирүче — хезмәтче түгел бит...

— Әкренрәк сөйләгез, Арамис! — диде Атос аны сүзеннән туктатып.

— Сүзегез хак... Хезмәтче түгел, хуҗа әфәндесе, хәтта хуҗа әфәнделәре җавап бирә! Хезмәтчеләребезнең безгә тугрылыгы безнең өчен үз җаннарын куркыныч астына куярлык дәрәҗәдәме соң? Алай ук түгел шул.

— Валлаһи, Планше өчен ышандырып диярлек әйтә алам,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Алайса, дустым, аның фидакарь тугрылыгына шактый гына акча да өстәгез,— анысы аңа беркадәр байлык бирәчәк,— шуннан соң аңа бер түгел, ике тапкыр ышана аласыз.

— Һәм шулай да барыбер алдаячаклар сезне,— диде Атос, әйберләр турында сөйләшкәндә ул оптимист, кешеләргә карата пессимист иде.— Акча алыр өчен алар бөтенесен дә вәгъдә итәләр, ә юлга чыккач куркулары эшкә комачаулык итә. Аларны тоту белән кыса башлыйлар, ә кыса башлагач инде, алар барысын да әйтеп бирәләр. Без бит инде бала-чага түгел, шайтан алгыры! Англиягә эләгер өчен,— Атос тавышын әкренәйтә төште,— бөтен җирдә кардиналның шымчылары һәм ярдәмчеләре кайнап торган Франциянe буеннан-буена узарга кирәк. Корабка утырыр өчен рөхсәт кәгазе кирәк. Лондонга бара белер өчен инглизчә сөйләшә белергә кирәк. Минемчә, бик кыен эш бу.

— Бер кыенлыгы да юк! — диде д'Артаньян бу сүзгә каршы. Бу ниятләренең эшкә ашуын бик тели иде ул.— Минемчә, киресенчә, бик җиңел эш ул. Әлбәттә, лорд Винтерга бөтен яманлыкларны, кардиналның бөтен кабахәтлекләрен...

— Әкренрәк! — диде Атос кисәтеп.

— ...бөтен интригаларны һәм дәүләт серләрен тәфсилләп язсаң,— дип д'Артаньян, Атосның киңәшен тотып, әкренрәк тавыш белән дәвам итте,— әлбәттә, безнең барыбызны терелэй тунаячаклар. Ләкин, Атос, алла хакы өчен, шуны онытмагыз: үзегез әйткәнчә, без аңа хатны гаилә эше буенча язабыз бит, хатыбызның бердәнбер максаты шул — миледи Лондонга килү белән лорд аны безгә этлек эшләү мөмкинлегеннән мәхрум итсен. Мин аңа хатны болайрак дип язам...

Арамис, башта ук йөзенә тәнкыйтьчән бер төс чыгарып:

— Я, тыңлап карыйк,— диде.

— «Галиҗәнап һәм кадерле дус...»

— Һе, инглиз кешесенә «кадерле дус» дип яз, имеш! — Атос шулай дип аны сүзеннән бүлдерде.— Әйтәсе дә юк, бик шәп башлыйсың! Браво, д'Артаньян! Болай дип олылаганыгыз өчен генә дә сезне терелэй тунау түгел, тураклап ташлаячаклар.

— Ярый, яхшы, сезнең сүз хак булсын. Алайса мин гади генә итеп: «галиҗәнап» дип язам.

— Сез хәтта «милорд» дип тә яза аласыз,— диде Атос. Кабул ителгән әдәп формасын саклауны һәрвакыт кирәк дип саный иде ул.

— «Милорд, Люксембург артындагы кечерәк бер яланны хәтерлисезме сез?»

— Бик шәп икән! Хәзер тагын Люксембургы да өстәлде! Моны корольнең анасына ишарә итү дип аңлаулары бар бит. Бик оста уйланган! — диде Атос көлеп.

— Ярый алайса, яхшы, гади генә итеп язабыз: «Милорд, теге кечерәк яланны, үзегезне исән калдырган төшне хәтерлисез микән?..»

— Д'Артаньян дустым, сездән беркайчан да андый сүз остасы чыкмаячак,— диде Атос.— «Үзегезне исән калдырган

төшне», имеш! Фи! Һич килешми болай! Тәрбияле кешегә андый яхшылыгың турында кайтарып әйтмиләр. Яхшылыгыңны кешенең исенә төшерү — аның хәтерен калдыру дигән сүз ул.

— Ай, дустым, бигрәк четерекле кеше инде сез! Сезнең цензурага буйсынып язасы булса, мин бу эштән бөтенләй ваз кичәм,— диде д'Артаньян.

— Бик яхшы итәсез. Сезнең төп эшегез, дустым, мушкет белән кылыч булсын, сез ул ике корал белән бик оста эш итәсез, ә каләм мәсьәләсен аббат җәнапларына тапшырыгыз, андый эшкә ул оста.

— Чыннан да, язу эшен Арамиска тапшырыгыз шул, латинча диссертацияләр дә яза бит ул,— дип җөпләп куйды Портос.

— Ярый, яхшы, ризамын! — диде д'Артаньян килешеп.— Арамис, безгә шул хатны язып бирегез әле. Ләкин иң изге атабыз папа исеме белән гозерләп әйтәм: сүзегездә бик сак булыгыз! Мин дә сезнең язганыгыздан гаеп эзләячәкмен, шуңа күрә искәртеп куям.

Арамис, шагыйрьләрчә ихласлык һәм үз-үзенә зур ышаныч белән:

— Бик ризамын, тик бөтен булган хәлне сөйләп бирегез,— диде.— Дөрес, милордның килене бик шома, икейөзле бер кеше икәнлеген ишеткәнем бар иде, аның кардинал белән сөйләшкәнен тыңлап торгач, үзем дә шуңа ышандым...

— Әкренрәк сөйләшегез, шайтан алгырысы! — дип сүзеннән бүлдерде аны Атос.

— ...ләкин нечкәлекләрен белеп җиткермим,— диде Арамис сүзен тәмамлап.

— Мин дә белеп бетермим,— диде Портос.

Д'Артаньян белән Атос беравык күзгә-күз карашып тордылар. Ниһаять, Атос уйлады да, гадәттәгегә караганда беркадәр агарына төшеп, башын кагып кына ризалыгын белдерде, һәм д'Артаньян җавап бирергә үзенә рөхсәт ителгәнлеген төшенде.

— Менә нәрсә турында язарга кирәк,— дип сүзгә кереште ул.— «Милорд, сезнең киленегез — җинаятьче, сезнең мөлкәтегезне үзенә мирас итеп алу өчен, ул кешеләр яллап сезне үтермәкче булды. Әмма аның сезнең туганыгызга иргә чыгарга хакы булмаган, чөнки ул моңарчы инде Франциядә бер тапкыр иргә чыккан булган һәм...»

Д'Артаньян, кирәкле сүзне эзләгән кебек, төртелеп калды, Атоска күтәрелеп карады.

— «...һәм ире аны йортыннан куып җибәргән»,— дип өстәп куйды Атос.

— «...хурлык тамгасы сугылганга күрә куып җибәргән»,— дип дәвам итте д'Артаньян.

— Булмас ла! — дип әйтеп куйды Портос.— Кеше яллап үзенең кайнагасын үтертмәкче булганмыни ул?

— Әйе.

— Ирдә булганмыни инде ул? — дип сорады Арамис.

— Әйе.

— Ире анын кулбашында лалә чәчкәсе рәвешендә хурлык тамгасы барлыгын да күргәнме? — дип сорады Портос.

— Әйе.

Бу «әйе» сүзен өч мәртәбәсен дә Атос әйтте һәм әйткән саен чырае караңгылана барды.

— Ул тамганы кем күргән соң? — дип сорады Арамис.

— Д'Артаньян белән мин, дөресрәге — хронологик тәртибен саклаганда, башта — мин, аннары — д'Артаньян,— диде Атос.

— Ул яман бәндәнең ире исәнме икән соң әле? — дип сорады Арамис.

— Исән.

— Тәгаен белеп әйтәсезме?

— Әйе, тәгаен белеп.

Беравыкка киеренке бер тынлык урнашты, шул тынлыкта һәркайсы күңеленнән әле әйтелгәннәрнең тәэсирен кичерде.

Беренче булып Атос телгә килде:

— Бу юлы инде д'Артаньян безгә хатның бик шәп каралмасын әйтеп бирде, язасы хатыбызны нәкъ әнә шулардан башларга кирәк.

— Шайтан алгыры, сүзегез хак бит, Атос! — диде Арамис.— Андый хат язу — бик четерекле эш ул. Мондый хикмәтле хатны канцлер кадәр канцлер җәнаплары да башкарып чыгарга читенсенер иде, гәрчә протоколларны бик шома язса да. Ярый алайса! Сез сөйләшеп комачауламагыз, мин язып карыйм.

Арамис, кулына каурый каләм алып, беравык уйланып торды да, хатын-кыз шикелле, бик нәфис хәрефләр белән тугызун юл хат язды, шуннан соң һәр сүзне үлчәп караган кебек, ашыкмыйча, акрынрак тавыш белән хатны укып күрсәтте:

«Милорд!

Сезгә шушы берничә юллык хат язучы кеше Ада урамындагы кечерәк бер яланлыкта сезнең белән кылычка-кылыч килгән иде. Шуннан бирле сез ул кешене күп тапкыр дустым дип атаган булганлыктан, ул да, яхшы киңәшен әйтеп, үзенең дуслыгын исбат итүне бурычы дип саный. Сез үзегезнең варисыгыз дип санаган якын кардәшегезнең ике тапкыр корбаны була язып калдыгыз, чөнки анын Франциядә инде иргә чыккан булып та Англиядә яңадан никахлашуы сезгә мәгълүм түгел. Әмма өченче тапкыр, ягъни хәзер, сезнең һәлак булуыгыз ихтимал. Сезгә кардәш тиешле ул хатын бүген төнлә Ларошельдән Англиягә чыгып китте. Анын килүен күздән ычкындырмагыз, чөнки ул хатын бик яман ниятләр белән бара. Сез анын нинди явыз эшләр эшли алуын беләсегез килсә, ул хатынның үткәндәге тормышын сул кулбашыннан укып белегез».

— Бик шәп килеп чыккан бит бу! — диде Атос хуплап.— Дәүләт секретареннан бер дә ким язмыйсыз икән, Арамис дус. Хәзер инде лорд Винтер, мондый кисәтүне алса, каты күзәтү оештырачак, бу хат хәтта ки кардинал хәзрәтләре кулына эләксә дә, безгә зарары тимәс иде. Ләкин безнең йомыш белән китәсе хезмәтченең Шательродан ары бармавы да ихтимал,

соңыннан ул әйтер: Лондонга барып кайттым, дияр. Шуңа күрә без аңа хат белән бергә акчаның яртысын гына бирик, калган яртысын җавап алып кайткач бирербез, диярбез. Сезнең теге асылташыгыз үз янызыздамы? — диде Атос д'Артаньянга.

— Минем янымда аннан да яхшырагы бар — акча бар,— дип, д'Артаньян акча янчыгын өстәлгә ташлады.

Алтын тәңкәләр чылтыравын ишетүгә, Арамис күтәрелеп карады, Портос дерт итеп куйды, Атос исә кымшанмады да.

— Бу янчыкта күпме акча бар? — дип сорады.

— Уникешәр франклы луидорлар белән җиде мең ливр.

— Җиде мең ливр! — дип «ах!» итте Портос.— Шул чүп кенә асылташның бәһасе җиде мең ливрмы?

— Шулайдыр, күрәсең, әнә өстәлдә ич. Дустыбыз д'Артаньян шуңа үз акчасын да өстәгәндер дип уйламыйм,— диде Атос.

— Шулай да, әфәнделәр, күп нәрсәне уйласак та, королеваны онытабыз икән без,— диде д'Артаньян, үз фикеренә кире кайтып.— Сөйгән яры Бекингэмның исәнлеген дә бераз кайгыртыйк. Без королева хакына эшләрдәй эшнең иң кечкенәсе генә бит бу.

— Бик дөрес сүз,— диде Атос килешеп.— Ләкин анысы инде аның Арамиска кагыла.

— Ә мин ни эшләргә тиешмен соң? — дип сорады Арамис кызарынып.

— Бик гади бер эш эшләргә: Турда яшәүче теге чая ханымга хат язарга тиешсез.

Арамис тагын кулына каурый каләм алды, тагы бераз уйланып торды да түбәндәге юлларны язып, шундук дуслары карамагына куйды.

— «Сөекле тудыкам!..»

— Әһә, ул чая ханым сезнең кардәшегез икән! — дип куйды Атос.

— Туганнан туган сеңлем,— диде Арамис.

— Ярый, туганнан туган сеңлегез булсын!

Арамис хатны укуында дәвам итте:

«Сөекле тудыкам!

Олуг хәзрәти кардинал җәнаплары,— Франциянең иминлеге хакына һәм король дәүләтенең дошманнарын җиңеп хур итү өчен ходай аны берүк саклый күрсен,— Ларошельнең фетнәче еретиклары белән эшне бетерде дип әйтерлек. Аларга ярдәм итүче Англия флоты крепостька якын да килә алмаячак. Шикләнмичә әйтә алам: берәр төрле бик зур хәл Бекингэм әфәндегә Англиядән чыгып китәргә комачаулык итәчәк. Изге атабыз кардинал җәнаплары — үткән заманның, бүгенге көннең һәм, ихтимал, киләчәкнең дә иң данлыклы дәүләт эшлеклесе. Әгәр кояш аңа комачаулык итсә, ул кояшны да каплар иде. Сөекле тудыкам, шул куанычлы хәбәрләрне апагызга җиткерегез. Мин бер төш күрдем, төшемдә шул мәлгунь инглиз үлде, имеш. Хәнҗәр белән кадап үтерделәрме, агулапмы,— анысын хәтерләмим,— тик шунысын гына тәгаен әйтә алам: төшемдә

мин аның үлгәнен күрдем, ә минем төшләрем һәрвакыт рас килгәнен үзегез беләсез. Мине озакламый күрәчәгегезгә ышанып торыгыз».

— Бик шәп бит бу! — диде Атос.— Сез — шагыйрьләрнең падишаһы, Арамис дус! Сез апокалипсис кебек сөйлисез һәм изге китап кебек чын дөресен әйтәсез. Хәзер инде бу хатка адрес язасы гына калды.

— Анысы бик ансат,— диде Арамис.

Ул кыланчыкланып кына хатны бөкләде дә тышына:

«Турдагы тегүче Мишон туташка»,— дип язып куйды.

Өч дус көлешеп бер-берсенә карашып алдылар: шулай итеп, аларның хәйләсе барып чыкмады.

— Хәзер инде төшенәсезме, әфәнделәр,— дип сүзгә кереште Арамис.— Бу хатны Турга фәкать Базен гына илтеп тапшыра ала: минем тудыкам бары тик Базенны гына белә, ул аңа гына ышана, башка хезмәтчеләр эшне харап кына итәчәк. Өстәвенә Базен бик укымышлы һәм дан-шөһрәт ярата, тарихны бик яхшы белә, әфәнделәр, Сикст Бишенченең, папа булып киткәнче, дуңгыз көткәнлеген дә белә. Базенның исәбе минем белән бергә рухани булып китү, шулай булгач, ул да папа булырга, яки, һич югы, кардинал булырга өметләнә. Аңлыйсызмы: исәбе шундый зур кеше тиктомалдан гына үзен тоттырмаячак, тота калсалар инде, газапланып үлсә үләр, әмма серен дошманга чишмәс.

— Яхшы, яхшы,— диде д'Артаньян килешеп,— мин Базенга риза, ул чагында сез Планшега риза булыгыз. Бервакыт миледи аны тукмап, өеннән куып чыгарырга кушкан булган, ә Планшеның хәтер яхшы, шуңа күрә, ышаныгыз, әгәр Планшега аннан үч алырга җай чыкса, ул үлсә үләр, әмма дошманыннан үч алмый калмас. Турдагы эшләр, Арамис, сезгә кагылса, Лондондагысы шәхсән миңа кагыла. Шуңа күрә бу эшкә Планшены сайлавыгызны сорыйм. Аның инде Лондонда булганы бар, дөп-дөрес итеп: «London, sir, if you please» * һәм «My master lord d'Artagnan» ** дип әйтә белә. Бер дә борчылмагыз, шулкадәр гыйлеме белән ул барганда да, кире кайтканда да юлны бик яхшы табачак.

— Алайса Планшега киткән чагында җиде йөз ливр бирик, кайткач — җиде йөзен, ә Базенга — киткән чагында өч йөз ливр, әйләнеп кайткач — өч йөзне,— дигән тәкъдимен әйтте Атос.— Шуннан безнең биш мең ливр байлык калачак. Һәркайсыбыз шуннан меңәр ливр алып, үзе теләгәнчә тотар, ә калган бер меңен, көтелмәгән чыгым-тотымга яисә уртак хаҗәткә дип, запаска салып, аббатка сакларга тапшырырбыз. Сез андый эшкә ризамы?

— Атос дус, сез грекларның бөек акыл иясе Нестор кебек фикер йөртәсез,— диде Арамис.

---

* Сэр, Лондонга бару юлын әйтегезче миңа (*инглизчә*).
** Минем хуҗа әфәндем лорд д'Артаньян (*инглизчә*).

— Димәк ки, Планше белән Базен китәләр,— дип йомгак ясады Атос.— Дөресен генә әйткәндә, Гримоның үз янымда калуына мин бик шатмын: ул минем мөгамәләгә күнеккән инде, мин дә аны яратам. Кичә ул шактый аргандыр, ә юлга чыкса, бөтенләй йончып бетәр иде.

Дүрт дус, Планшены чакырып алып, аңа тиешле күрсәтмәләрен бирделәр; д'Артаньян аны алдан ук искәртеп куйган иде инде: иң элек аның зур шөһрәт казанасын әйткән иде, аннары акчасы белән кызыктырган иде һәм ахырдан гына шактый куркынычлы сәфәр булачагын искәрткән иде.

— Хатны җиң кайтармасына яшерермен, тотсалар, кабып йотармын,— диде Планше.

— Ул чагында бит син йомышны башкарып чыга алмаячаксың,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы.

— Бүген кич сез миңа хатның күчермәсен бирегез, иртәгә мин аны яттан беләчәкмен.

Д'Артаньян, «Я, ничек? Дөрес әйткәнменме мин сезгә?» дигән сыман, дусларына карады.

— Тик шуны бел,— диде аннары Планшега: — сиңа лорд Винтер янына барып җитәргә сигез көн вакыт бирелә, кайтырыңа — сигез көн, шулай итеп, барлыгы — уналты көн. Китүеңнең уналтынчы көнендә кичке сәгать сигезгә кайтып җитмәсәң, тугызынчы биш минутта кайтып керсәң дә, калган акчаны бирмәячәкбез.

— Ул чагында, әфәндем, сәгать алып бирегез миңа,— диде Планше.

Атос, гадәтенчә юмартланып:

— Мә, менә моны ал,— дип, Планшега үз сәгатен сузды,— һәм сгетлек күрсәт. Тик шуны онытма: әгәр серне кешегә чишсәң, берәрсенә ялгыш ычкындырсаң, я булмаса берәр җирдә трай тибеп йөрсәң, хуҗаңны харап итәчәксең,— ул синең тугрылыклы булуыңа ышанып, сине шундый эшне башкарып чыга ала, дип безгә мактады. Тагын шуны да онытма: әгәр синең аркәда д'Артаньянга бер-бер хәл була калса, мин сине теләсә кайдан табып, эчеңне тишәчәкмен.

Планше, үзеннән шикләнүләренә хәтере калып һәм мушкетерның җитди чыраеннан куркуга төшеп:

— Их, әфәндем! — дип куйды.

— Ә мин синең тереләй тиреңне туныйм! — диде Портос, күзләрен бик усал йөртеп.

— Аһ, әфәндем! — диде Планше.

— Ә мин, вәхши кешеләрчә, көйрәп кенә торган ут өстендә яндырып үтерәчәкмен! — диде Арамис ягымлы, юаш тавышы белән.

— Һай, әфәндем!— дип куйды Планше һәм елап т җибәрде; шушы сүзләрдән куркып елагандырмы ул, әллә дүрт дусның шул хәтле тату булуларына күңеле бик нечкәреп киттеме,— анысын тәгаен генә әйтә алмыйбыз.

Д'Артаньян аның кулын кысып, кочаклап алды.

— Беләсеңме, Планше, бу әфәнделәр мине бик яратканга күрә шулай дип әйтәләр сиңа, ләкин, асылда, сине яраталар,— диде ул аңа.

Планше шушы төн эчендә хатны ятлап өлгерсен дип, аны иртәгә иртән сәгать сигездә юлга чыгарып җибәрергә карар иттеләр. Болай булгач, Планше нәкъ унике сәгать вакыт отты, чөнки ул уналтынчы көнне кичке сәгать сигезгә кайтып җитәргә тиеш иде.

Иртәгесен иртән Планше атка атланган чакта, күңелендә Бекингэмга карата бертөрле якынлык хисе саклаган д'Артаньян, хезмәтчесен бер читкәрәк алып китеп, әйтте:

— Карале, хатны лорд Винтерга тапшырып, ул укыгач, син аңа әйт: «Лорд Бекингэм җәнапларын саклый күрегез: аны үтерергә җыеналар»,— диген. Беләсеңме, Планше, бу бик зарур, бик җитди нәрсә — мондый серемне сиңа ышанып тапшыруымны хәтта дусларыма да әйтмәдем, үземне капитанлыкка күтәрергә вәгъдә итсәләр дә, мин аны хатка да язмас идем.

— Борчылмагыз, әфәндем, миңа бөтенесен дә ышанып тапшырырга була икәнен менә үзегез дә күрерсез.

Шулай дигәч, Планше бер дигән шәп атка атланып алды да,— бу атны ул лагерьдан егерме льеда калдырып, шуннан ары почта атлары белән китәргә тиеш иде,— кушаяклатып чаптырып китте; өч мушкетерның үзен нишләтәчәкләре исенә төшкән саен йөрәге әрнештергәләп алса да, тулаем кәефе бик шәп иде аның.

Базен Турга икенче көнне иртән китте; кушкан йомышны башкарып кайту өчен аңа сигез көн вакыт бирелде.

Йомышка җибәргән хезмәтчеләре әйләнеп кайтканчы, дүрт дус, билгеле, гадәттәгедән саграк, уяурак булдылар.

Алар көнозын тирә-якта кешеләрнең ни сөйләшүләрен тыңлап йөрделәр, кардиналның ниләр эшләвен күзәткәләделәр. Ришелье янына берәр атчабар килмәгәнме икән дип иснәнделәр. Көтмәгәндә генә хезмәт вазифасын үтәргә дип килеп чакырсалар, йөрәкләренә курку төшә торган булды. Өстәвенә аларга әле үз-үзләрен дә сакларга кирәк: миледи кешегә бер канукса һич тынгылык бирми торган өрәк сыман бер зат иде.

Сигезенче көнне иртән, дүрт дус «Мөртәт» мәйханәсендә ашап утырганда, гадәтенчә көр күңел белән елмаеп Базен килеп керде дә алдан сөйләшенгән шартлы тел белән әйтте:

— Арамис әфәнде, менә тудыкагызның җавабы,— диде.

Дуслар сөенешеп күзгә-күз карашып алдылар: болай булгач, эшнең яртысы эшләнде, димәк; дөрес анысы — эшнең бу яртысы җиңелрәк һәм башкарып чыгу өчен азрак вакыт сорый иде.

Арамис эре-эре хәрефләр һәм орфографик хаталар белән язылган хатны, бераз кызарынып, Базенның кулыннан алды.

— Һай аллам! — дип көлеп әйтеп куйды үзе.— Бу бичара Мишон де Вуатюр әфәнде шикелле итеп язарга беркайчан да өйрәнә алмас, ахры!

Хатны алган чакта дүрт дус белән әңгәмә кылып утырган швейцарлы:

— Пичара Мишон тигәнегес кем соң ул? — дип сорады.

— И аллам, әллә кем түгел лә, бик сөйкемле яшь кенә бер тегүче кыз, мин аны бик ярата идем, истәлеккә берничә генә юл хат язып җибәрүен үтенгән идем.

— Сайтан алкыры, хәрефләре сикелле үзе дә сундый сур тама пулса, сес пик пәхетле кесе, иптәс! — диде швейцарлы.

Арамис хатка күз йөртеп чыкты да Атоска бирде.

— Укыгыз әле, Атос, ниләр язган икән ул кызый,— диде Арамис.

Атос та хатка күз йөртеп чыкты һәм, эчтәлегенә карата бернинди шик-шөбһә калмасын дип, аны кычкырып укый башлады:

— «Сөекле тудыкам, минем апам да, үзем дә төшне бик дөрес юрыйбыз һәм андый төшләрдән бик куркабыз, ә менә сезнеке турында, төшнең бөтенесе ялган, дип әйтергә мөмкиндер дип беләм. Хушыгыз, исән-сау йөрегез, ара-тирә безгә хат-хәбәр җибәргәләп торыгыз.

*Аглая Мишон».*

Хатны укыган чакта болар янына килгән драгун:

— Нинди төш турында яза ул? — дип сорады.

— Әйе, нинди төс турында? — дип җөпләде швейцарлы.

— И аллам, әллә нинди төш түгел инде, мин аңа үзем күргән бер төшне сөйләгән идем,— диде Арамис.

— И аллам, күргән төсеңне сөйләве бик зиңел дә сул, мин пер дә төс күрмим сул.

— Бик бәхетле кеше икәнсез, алай дип әйтә алсам, мин бик шат булыр идем әле,— диде Атос, өстәл яныннан кузгалып.

Атос шикелле кешенең үзеннән көнләшүенә исе китеп, швейцарлы:

— Перкайшан да! Перкайшан да төс күрмим мин! — дип тәкрарлады.

Атосның өстәл яныннан торуын күреп, д'Артаньян да кузгалды һәм, дустын култыклап алып, аның белән бергә чыгып китте.

Портос белән Арамис драгун белән швейцарлының дорфа шаяртуларына җавап биреп сөйләшә калдылар.

Базен исә кайтып китеп, салам түшәгенә йокларга ятты. Швейцарлыга караганда хыялга баерак булганлыктан, ул бик матур төш күрде: Арамис папа булган да Базенны кардиналлыкка багышлый, имеш.

Әйткәнебезчә, Базен, исән-сау йөреп кайтса да, дүрт дусның күңелен тынычсызлап торган борчуны бөтенләй бетерә алмады. Көмнедер көткән чакта көннәр бик озак уза, моны бөтенесеннән дә бигрәк д'Артаньян кыен кичерә, хәзер тәүлекнең озынлыгы кырык сигез сәгать дип, ул һич икеләнмичә бәхәсләшә дә алыр иде. Егет, кайвакыт дингездә акрынрак йөзәргә дә туры

килүен онытып, милединың кодрәтен арттырып бермә-бер күрә башлады. Күңеленнән гыйфрит булып тоелган бу хатынга аның үзе шикелле үк кодрәтле ярдәмчеләр уйлап чыгарды, шылт иткән тавыш ишетсә дә, мине кулга алырга килделәр, дусларым һәм минем белән күзгә-күз очраштырып сөйләштерү өчен Планшены кире китерделәр, дип уйлады. Алай гына да түгел: Пикардия егетенә булган ышанычы да көннән-көн кими барды. Аның күңелендә үсә барган бу шом Портос белән Арамиска да күчте. Тик бер Атос кына, тирә-юнендә бернинди куркыныч-мазар булмаган кебек, әүвәлгечә тып-тыныч йөри бирде.

Уналтынчы көндә инде д'Артаньян белән дусларының күңел тынгысызлыгы шулкадәр көчәйде — алар, бер урында гына тора алмыйча, шәүлә шикелле, Планше кайтасы юл буенда тулгана башладылар.

— Хатын-кыздан да шулай курыккач, сез, валлаһи, ир кеше түгел, сабый бала! — диде аларга Атос.— Чынлап торып уйлаганда нәрсәдән куркабыз соң әле без? Төрмәгә эләгүдәнме? Аннан коткарачаклар сезне, Бонасье ханымны коткардылар ич әле. Башыбызны кисәрләр дисезме? Траншеяда тып-тыныч ятканда без көн саен аннан да яманрак куркыныч астында яшибез, чөнки, ник дигәндә, туп ядрәсе төшеп ботыбызны сындыруы ихтимал; минем уемча, хирург аякны кискән чакта палач башны кискәндәгегә караганда безне күбрәк газаплаячак. Бер дә борчылмыйча тыныч кына көтегез: я ике, я дүрт сәгатьтән, иң соң дигәндә — алты сәгатьтән Планше кайтып җитәр, кайтып җитәм дип сүз бирде бит, мин Планшеның сүзенә ышанам, әйбәт егет кебек күренә ул.

— Әгәр кайтмаса? — диде д'Артаньян.

— Әгәр инде кайтмаса, нинди дә сәбәп аркасында тоткарланып калган дигән сүз, менә шул. Аның аттан яки күпердән егылып төшүе, атта бик каты чабып үпкәсенә салкын тидерүе ихтимал. Әй, әфәнделәр, андый көтелмәгән сәбәпләр килеп чыгуын да онытырга ярамый. Дөнья ул — әнә шундый вак-төяк бәла-казалардан тезелгән тәсбих кебек, философ кеше елмаеп шуларны берәм-берәм тартып кына утыра. Минем кебек философ булыгыз, әфәнделәрем, әйдәгез, өстәл янына утырышып, бер эчик: киләчәк дигәнең шамбертен бокалы аша караганда гына аллы-гөлле булып күренә миңа.

— Бик дөрес сүз анысы,— диде д'Артаньян бу сүзгә каршы,— тик яңа шешә ачкан саен миледи базыннан килмәдеме икән бу дип шикләнү дә туйдырды шул мине.

— Бик талымчан кеше икәнсез, шундый чибәр хатын бит ул! — диде Атос.

Портос:

— Кешеләр тамга салган хатын! — дип тупас кына шаяртты да гадәтенчә шаркылдап көлеп җибәрде.

Атос, калтыранып куеп, тирен сөрткән шикелле, кулы белән

маңгаен сыпырды да, тыела алмыйча, гасабилы бер хәрәкәт белән урыныннан сикереп торды.

Ул арада көн дә узып китте; кич, гадәттәгедән акрынрак килгән кебек тоелса да, ахырында барыбер килеп җитте, трактирларга кешеләр килеп тулды. Асылташ саткан акчадан үз өлешен алган Атос «Мөртәт»тән чыкмады. ·Безнең дусларны бер дигән аш мәҗлесенә чакырып сыйлаган де Бюзиньи әфәндене ул үзенә бик лаек партнер дип тапты. Шулай итеп, алар икәү шакмак уены уйнаганда, кичке сәгать җидене сукты; сакчы постларны көчәйтергә баручы патрульләрнең трактир яныннан узулары ишетелеп калды; сәгать сигезенче яртыда кичке гыйбадәткә чаң суктылар.

— Болай булгач, бетте...— дип пышылдады д'Артаньян Атоска.

— Акчабыз әрәм булды, димәкче идегез сез,— дип, Атос тыныч кына аның сүзен дөресләп әйтте, кесәсеннән дүрт пистоль акча чыгарып өстәлгә ташлады да: — Әфәнделәр, кичке гыйбадәткә чаң сугалар, әйдәгез, кайтып йоклыйк,—диде.

Шуннан соң Атос белән д'Артаньян трактирдан чыгып киттеләр. Алар артыннан, култыклашып, Арамис белән Портос та чыкты. Арамис авыз эченнән генә ниндидер бер шигырь сөйли, Портос исә, нишләргә белмичә, мыек очын тарткалый иде.

Шул вакыт караңгыда ниндидер бер кеше күренде, гәүдәсе д'Артаньянга таныш кебек тоелды, һәм шунда аның колагы няләшкән таныш тавыш егеткә:

— Әфәндем, мин сезгә плащ китердем, бүген кич салкынчарак,— диде.

Д'Артаньян, шатлыгыннан нишләргә белмичә:

— Планше! — дип кычкырып җибәрде.

Портос белән Арамис та:

— Планше! — дип куйдылар.

— Әйе шул, Планше,— диде Атос.— Моның нәрсәсе гаҗәп? Сәгать сигезгә кайтып җитәм дип сүз биргән иде бит ул, әнә сәгать сигезне суга. Браво, Планше, сез сүзегездә тора торган кеше икәнсез, киләчәктә хуҗагыздан китә алсагыз, мин сезне үземә хезмәтче итеп алачакмын.

— Юк, булмый! — диде Планше бу сүзгә каршы.— Мин д'Артаньян әфәндене беркайчан да ташлап китмәячәкмен.

Шул минутта ук д'Артаньян Планшеның аның кулына хат төрткәнен сизде.

Д'Артаньянның Планшены киткән чактагы шикелле кочаклап аласы килсә дә, урам уртасында хезмәтчесен шулай яратуы узган-барганнарга гаҗәп тоелыр дип, бу теләгеннән тыелып калды.

— Хат миндә,— диде ул Атос белән калган ике дустына.

— Яхшы, өйгә кайткач укырбыз,— диде Атос.

Хат д'Артаньянның уч төбен пешереп тора кебек иде, ул кызурак атлап китмәкче булган иде дә, Атос аны култыклап

алды, һәм егеткә, теләсә-теләмәсә дә, дусты белән бергә атларга туры килде.

Ниһаять, алар, палатага кайтып кереп, ут яндырдылар. Өсләренә чит кеше килеп кермәсен дип, Планше ишек төбенә сакка басты, д'Артаньян исә калтыранган кулы белән печәтне куптарып, зарыгып көткән хатны ачты.

Хатта саф британнарча почерк белән нибары ярты гына юл язылган һәм кыска гына итеп: «Thank you, be lasy», ягъни: «Бик зур рәхмәт, тыныч булыгыз», диелгән иде.

Атос хатны д'Артаньян кулыннан алды да шәмгә китереп, янып беткәнче тотып торды. Аннары Планшены чакырып алып:

— Дустым, хәзер инде үзеңә тиешле теге җиде йөз ливрны сорый аласың, шулай да ул хат белән синә әллә ни куркыныч булмаган! — диде.

— Шулай булса да, аны исән-сау алып кайтып җиткерү өчен төрле хәйләләр кулланырга бер дә комачауламады ул миңа,— дип җавап кайтарды Планше.

— Яле, алайса күргәннәреңне сөйләп җибәр әле,— диде д'Артаньян.

— Аларны сөйләсәм, бик озак булыр, әфәндем.

— Дөрес әйтәсең, Планше,— диде Атос,— өстәвенә, кичке гыйбадәткә чаң да суктылар, әгәр безнең ут башкаларныкына караганда озаграк янса, аңа игътибар итүләре мөмкин.

— Ярый, алайса йокларга ятыйк. Тынычлап йокла, Планше! — диде д'Артаньян.

— Анттыр әгәр, әфәндем, менә уналты көнгә беренче тапкыр тынычлап йоклыйм.

— Мин дә шулай! — диде д'Артаньян.

— Мин дә! — дип кычкырды Портос.

— Мин дә! — дип куйды Арамис.

— Яшерен-батырын түгел, мин дә шулай,— дияргә мәҗбүр булды Атос та.

## *XIX*

## *ТӘКЪДИР ШАЯРТУЫ*

Бу вакытта миледи, усал ана арслан шикелле, палубада әле анда, әле монда сугылып, ачу-ярсуыннан үзен кая куярга белмәде; аның, менә хәзер үк диңгезгә сикереп, ярга йөзеп чыгасы килде: ул үзенең д'Артаньян тарафыннан мәсхәрә ителүе, Атосның куркыту-янавы һәм алардан уч алмыйча Франциядән китеп баруы белән һич килешә алмады. Тора-тора ул шушы ачу-гарьлегенә түзә алмас бер хәлгә җитте һәм, төрле хәвеф-хәтәргә тару ихтималын да уйлап тормастан, капитаннан «мине ярга төшерегез» дип ялына башлады. Ләкин капитан, күселәр белән кошлар арасында калган ярканат кебек, французлар белән инглизләрнең хәрби кораблары уртасындагы кыенлыктан тизрәк чыгарга тырышып, Англия ярларына барып

җитәргә ашыга иде, шуңа күрә хатын-кыз капризы булып кына тоелган бу үтенечтән бөтенләй баш тартты; хәер, үз карамагына кардинал тарафыннан махсус тапшырылган бу пассажир хатынга ул, диңгез белән французлар комачауламаса, Бретон портларының берсендә — я Лорианда, я Брестта төшереп калдырырга сүз бирде. Ләкин җил каршыга исә; диңгез бик давыллый, судноны әле болайга, әле тегеләйгә борырга туры килә иде. Шарантадан кузгалып киткәнгә тугыз көн дигәндә, борчу-хафаланулардан агарынган, ачуыннан тәмам ярсыган миледи еракта бары тик Финистерның күгелҗем ярларын гына күрде.

Исәпләп карады: Франциянең бу төбәгеннән кардинал янына кайтып җитү өчен ким дигәндә өч көн вакыт кирәк булачак иде; шуңа тагын корабтан ярга төшәргә бер көн китүен дә өстәсәң — дүрт көн була; бу дүрт көнне узып киткән тугыз көнгә кушсаң — унөч көн бушка киткән булып чыга! Шул унөч көн эчендә Лондонда нинди хәлләр булмас! Кире әйләнеп кайтсам, кардиналның, һичшиксез, бик яман ачуы килер, шуннан инде минем зарымны тыңлаудан бигрәк, тегеләрнең миңа каршы шикаятьләренә күбрәк колак салыр, дип уйлады миледи, шуңа күрә кораб Лориан һәм Брест яннарыннан узган чакта ул инде капитаннан, мине төшереп калдырыгыз, дип сорамады, капитан да, үз нәүбәтендә, юри ул хакта берни әйтмәде. Шулай итеп, миледи әлеге юлы белән бара бирде, Планше Портсмутта Франциягә китүче корабка утырган көнне кардинал хәзрәтләренең йомышчысы тантаналы төстә шушы портка килеп кенә керде.

Бу көнне бөтен шәһәр гадәттә булмаганча мәш килә: әле яңа гына ясалып беткән зур-зур дүрт корабны суга төшереп яталар иде; молда гадәттәгечә асылташлар белән бизәлгән алтын укалы киеменнән, ак каурые муенына таба төшеп торган эшләпәдән, үзе шикелле үк зат киенгән яраннары уртасында герцог Бекингэм басып тора иде.

Дөньяда кояш та барлыгын инглизләрнең исенә төшерә торган бик сирәк кышкы матур бер көн иде. Күк йөзен һәм диңгез өстен алсу нурларга манчып, кояш инде баеп килә, аның соңгы алтынсу нурлары каладагы манараларга һәм борынгы йортларга төшеп, тәрәзә пыялаларында янгын шәүләсе сыман булып чагыла иде.

Миледи, ярга якынайган саен сафлана-хушлана барган диңгез һавасын сулый-сулый, хатын-кыз башы белән, бер ялгызы үзе юк итәргә тиешле шушы дәһшәтле сугыш әзерлекләрен, бу армиянең берничә янчык алтын белән үзе юкка чыгарырга тиешле бөтен көч-куәтен күздән кичергәндә, күңеленнән үзен ассүриялеләр лагерена үтеп кергән һәм шунда бер кул селтәве белән төтен кебек юкка чыгарга тиешле исәпсез-хисапсыз гаскәр, сугыш арбалары, ат һәм кораллар күргән Юдифь белән чагыштырды.

Судно рейдка туктады; якорь ташларга дип торганда гына аның янына бик шәп коралланган кечерәк бер куттер килде дә,

үзен сакчы судно дип белгертеп, суга көймә төшерде һәм бу көймә трапка таба турылап йөзеп килә дә башлады. Көймәдә бер офицер, боцман һәм сигез ишкәкче бар иде; офицер бортка менде, анда аны хәрби формага күрсәтелергә тиешле игътибар-хөрмәт белән каршы алдылар.

Капитан белән берничә минут сөйләшеп торгач, офицер аңа ниндидер кәгазьләр укытты һәм шуннан соң инде капитан боерыгы белән судноның бөтен командасын һәм пассажирларны палубага чакырып чыгардылар.

Алар шунда тезелешеп баскач, офицер бу бригның каян чыгуын, нинди курс белән килүен, кайларга тукталуын кычкырып сорады. Капитан аның барлык сорауларына бер дә икеләнмичә һәм кыенсынмыйча җавап бирде. Аннары офицер палубадагы кешеләрне берәм-берәм карарга керешге, миледи янына җиткәч, бик игътибар белән аңа текәлеп карады, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Аннары ул яңадан капитан янына килеп, аңа тагын нәрсәдер әйтте һәм, аның вазифаларын үз өстенә алган сыман, ниндидер маневр ясарга команда бирде. Экипаж бу команданы шундук үтәде. Судно арырак китте, кечкенә куттер, алты тубының көпшә авызларын суднога таба каратып, аның белән бортка борт янәшә барды, ә көймә судноның артыннан иярде, аның белән чагыштырганда ул кечкенә бер төртке кебек кенә иде.

Офицер миледины карый торганда, аңлашылганча, ханым үзе дә күзләре белән ашардай булып аңа карады. Кешенең күңелендәген йөзенә карап белә торган уттай карашлы бу хатын, никадәр сизгер булса да, бу юлы бик тыныч чырайлы кешегә туры килеп, аның йөзенә карап кына берни белә алмады. Милединың каршына туктап, бер сүз эндәшмичә, бик игътибар белән хатынның килеш-кыяфәтен тикшереп торган бу офицерга егерме биш-егерме алты яшьләр чамасы булыр, үзе ак чырайлы, күзләре зәңгәр, бераз төпкә батыбрак тора, нәфис, таман гына иреннәре гел йомылган-кысылган килеш; бик нык алга чыгып торган ияге ихтыяр көчен сиздереп тора,— гадәттә гади британ халкы тибында барыннан да бигрәк үзсүзлелек, үҗәтлек билгесе бу; шагыйрьләр, хыялый кешеләр һәм солдатларныкы шикелле сөзәгрәк маңгаен чак кына кыска сирәк чәч каплап тора, ияге белән бергә яңакларының аскы өлешен каплап торган сакалы да чәче төсле коңгырт-кара.

Судно белән аңа ияргән куттер гаваньга килеп кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Яңгырлар башланыр алдыннан ай томан пәрдәсенә өртелгән шикелле, мачталардагы сигнал фонарьларын һәм мол утларын төтен сыман томан каплап алганлыктан, төн караңгысы тагы да куерак кебек тоела. Һава дымык һәм салкын иде.

Миледи, чыныккан таза бер хатын булса да, ирексездән тәне чирый башлаганын тойды.

Офицер үзенә милединың әйберләрен күрсәтергә, аның багажын көймәгә илтергә кушты, бу эш эшләнгәч, милединың үзен дә көймәгә төшәргә чакырды, аңа кулын сузды.

Миледи аңа күтәрелеп карады да икеләнгән кебек туктап калды.

— Сез кем буласыз, галиҗәнап? Ни өчен сез миңа бу кадәр илтифат күрсәтәсез? — дип сорады ул.

— Сез моны, ханым, минем мундирыма карап та төшенергә тиешсез, мин Англия флоты офицеры,— дип җавап кайтарды егет.

— Шундый гадәт бармыни? Англия флотының офицерлары шулай Бөек Британиянең берәр гаванена кайтып төшкән ватандашлары карамагына тапшыралармыни үзләрен, бик зур илтифат күрсәтеп, ярга ук чыгарып куялармыни?

— Әйе, шулай, миледи, тик ул илтифат йөзеннән түгел, бәлки саклык өчен эшләнә: сугыш вакытында чит ил кешеләрен алар өчен махсус билгеләнгән кунак йортына илтеп куялар, алар турында иң төгәл мәгълүматлар җыелып беткәнче, аларны күзәтү астында тоталар.

Миледи Портсмуттан алып Манчестерга чаклы булган төбәкләрдә моңарчы беркайчан да ишетелмәгән иң саф инглиз телендә:

— Мин бит чит ил кешесе түгел, галиҗәнап,— диде,— минем исемем леди Кларик, мондый чарагыз....

— Мондый чара бөтен кеше өчен дә уртак, миледи, сез үзегез теләгәнгә юл куйсыннар дип юкка тырышасыз.

— Ул чагында инде мин сезнең белән китәргә тиеш булам, галиҗәнап.

Миледи, офицерның кулына тотынып, траптан төшә башлады, аста аны көймә көтеп тора иде. Офицер аның артыннан төште; аннары, көймә койрыгына зур плащ җәеп, миледины шуңа утыртты да үзе дә аның янына урнашты. Матросларга:

— Ишегез,— диде.

Сигез ишкәк берьюлы суга чумып, сигезе бер тавыш булып чупылдый, сигезе бер хәрәкәт белән күтәрелеп төшә башлауга, көймә су өстеннән очып кына барган кебек йөзеп китте.

Биш минуттан ярга килеп тә туктады.

Офицер ярга сикереп чыкты да миледига кулын сузды.

Аларны инде монда карета көтеп тора иде.

— Бу карета безгәме? — дип сорады миледи.

— Әйе, ханым,— диде офицер.

— Кунак йорты шулай бик еракмыни?

— Шәһәрнең аргы башында.

Миледи:

— Киттек алайса,— диде дә тәвәккәлләп каретага кереп утырды.

Офицер кунак хатынның әйберләре карета артына әйбәтләп бәйләнгәнен карап торды, аннары бу эш беткәч, миледи янына утырып, каретаның ишеген япты.

Кучер, кая барырга кушканны көтмәстән, хәтта ул турыда сорап та тормастан, атларын шәһәр урамнары буйлап җилдертеп чаптырып китте.

Үзен шушы рәвешле һич көтелмәгәнчә каршы алулары миледины бик нык уйга калдырды. Яшь офицерның сөйләшергә бернинди теләге юклыгын күреп, миледи карета почмагына терәлебрәк утырды да бу хәлне төрлечә юрый башлады.

Чирек сәгатьләп вакыттан соң, болай озак баруларына гаҗәпсенеп, миледи, үзен кая алып баруларын карамакчы булып, карета тәрәзәсенә иелде. Юл буенда инде йортлар күренми, караңгыда агачлар берсен-берсе куышып чапкан зур-зур кара өрәкләр сыман булып тоелалар иде.

Миледи калтыранып куйды.

— Без шәһәрне чыгып киттек бит инде,— диде ул.

Офицер эндәшмәде.

— Мине кая алып баруыгызны әйтмәсәгез, моннан да ары бармыйм мин, сезне кисәтеп куям, галиҗәнап!

Ханымның болай дип янавы да җавапсыз калды.

— О, бусы инде чамадан ашты! Каравыл! Коткарыгыз! — дип кычкырды миледи.

Аның кычкыруына каршы беркем җавап кайтармады, карета юл буйлап җилдереп бара бирде, офицер исә таш сынга әйләнеп катып калган сыман иде.

Миледи мондый очракларда кешегә бик сирәк тәэсирсез кала торган усал бер төс белән офицерга карады; караңгыда ачу-ярсудан күзләре ялт-йолт килде.

Ә егет һаман тыныч кына бара бирде.

Миледи каретаның ишеген ачып сикереп төшмәкче булды.

— Сикерә күрмәгез, ханым, бәрелеп үләрсез,— диде егет салкын гына.

Миледи, ачуына буылып, кире урынына утырды, офицер исә иелеп аның йөзенә карады; әле генә шундый чибәр, сөйкемле булып күренгән йөзнең дуамал бер ачу белән бозылып бөтенләй диярлек ямьсезләнеп-котсызланып калуына исе киткән сыман иде аның. Мәкерле хатын, эчендәге кичерешләрен чыраена чыгарып, үз-үзен харап итәчәген аңлап алды; йөзенә юаш-сабыр бер төс чыгарды да зарланган төсле тавыш белән сүзгә кереште:

— Алла хакы өчен, әйтегез әле: мине шушылай көчләп каядыр алып баруыгызны мин кем эше дип — сезнеке дипме, сезнең хөкүмәтегезнеке дипме, я булмаса берәр дошманым эше дипме аңларга тиеш?

— Сезне, ханым, берәү дә көчләми, сезне болай каршы алуыбыз фәкать саклык чарасы гына — Англиягә килүче бөтен кешегә карата кулланабыз без аны.

— Сез бит мине бөтенләй белмисез?

— Минем сезне беренче тапкыр күрүем.

— Алайса, дөресен генә әйтегез әле, сезнең мине дошман күрерлек берәр төрле сәбәбегез бармы әллә?

— Ант итеп әйтәм: бернинди дә сәбәбем юк.

Офицер егетнең тавышы бик тыныч, сабыр һәм йомшак та иде хәтта, шуңа күрә миледи тынычлана төште.

Ниһаять, берәр сәгать чамасы баргач, карета бер тимер рәшәткә каршына килеп туктады. Такыр юл таш тау шикелле кырыс бер кыяфәт белән калкып торган аулак замокка җитеп, шунда беткән иде. Карета тәгәрмәчләре вак ком өстеннән бара башлады, миледи көчле бер шау ишетте һәм бу тавышның кыя ярга дулкыннарын кагып торган диңгез шавы икәнен төшенде.

Карета гөмбәзле ике түбә астыннан узып, ниһаять дүрт почмаклы караңгы бер ишегалдына кереп туктады; шундук каретаның ишеге ачылып, егет елт кына сикереп төште дә миледига кулын сузды; миледи, аның кулына тотынып, тыныч кына, каретадан чыкты.

Як-ягына күз салгалап алгач, ул офицер егеткә карады да, иң матур елмаюын бүләк итеп:

— Шулай да мин әсир төшкәнмен икән,— диде. Аннары шуңа өстәп әйтте: — Тик мин моны озакка сузылмас дип беләм. Минем вөҗданым һәм сезнең илтифатыгыз бу эштә миңа таяныч булыр дип ышанам.

Офицер егет, бу комплиментка ни дип тә җавап бирмәстән, хәрби корабларда боцманнар куллана торган сыбызгы шикелле көмеш сыбызгысын бил каешы астыннан чыгарды да өч тапкыр — өчесендә өч төрле итеп — сызгыртты; шундук хезмәтчеләр килеп җитеп ак күбеккә төшкән атларны туарып алдылар һәм каретаны сарайга кертеп куйдылар.

Офицер баягыча сабыр гына, әдәпле генә итеп әсир хатынны йортка керергә чакырды. Миледи да, баягыча матур елмаеп, офицерны култыклап алды да аның белән бергә тәбәнәк кенә ишектән кереп китте. Ишектән кергәч, түр башы гына яктыртылган гөмбәзле коридор башланып, ул борылмалы таш баскычка илтә иде; миледи белән офицер шул баскычтан өскә менделәр дә авыр бер ишек каршына килеп туктадылар; егет ишекнең йозагына ачкыч тыгып боруга, ишек авыр гына ачылып китте дә миледига дип билгеләнгән бүлмәнең эче күренде.

Әсир хатын бер күз ташлау белән бөтен бүлмә эчен вагытөягенә хәтле күреп алды.

Бүлмәнең җиһазы бер үк дәрәҗәдә төрмә өчен дә, иректәге кеше яшәр өчен дә ярарлык иде, тик тәрәзәләрендәге рәшәткәсе белән ишегендәге тышкы эшермәләре генә төрмәдер бу дигән уй тудыра иде.

Иң каты сынауларны да узган, чыныккан бу хатын бер мәлгә каушап-югалыбрак калды; лып итеп креслога утырды һәм, кулларын кушырып, башын игән хәлдә, менә хәзер бүлмәгә судья килеп керер дә сорау ала башлар дип, йөрәге калтырана-калтырана көтә башлады.

Әмма бүлмәгә, диңгез пехотасының ике-өч солдатыннан башка, керүче кеше булмады. Ул солдатлар сандык белән төен

чекләрне бүлмәнең почмагына куйгач, тып-тын гына чыгып та киттеләр.

Офицер егет һаман шулай тыныч-сабыр гына, бер сүз сөйләшмичә, кулын изәп яки сыбызгысын сызгыртып кына солдатларга тегене-моны кушып торды.

Бу кеше белән аның кул астындагылар тел дигән нәрсәне бөтенләй онытканнар, яисә аның кирәге калмаган дип уйларлык иде.

Ниһаять, миледи түзмәде, тынлыкны бозып:

— Галиҗәнап, алла хакы өчен, аңлатып бирегез әле: ниткән эш була бу? — дип сорады.— Мондый аптыраштан коткарыгыз мине! Минем үзем күргән теләсә нинди куркынычны, үзем аңлаган теләсә нинди бәхетсезлекне кичерерлек көчем бар. Бу нинди җир һәм бирегә мин кем буларак килеп эләктем? Әгәр мин ирекле икәнмен, ул чагында бу тимер рәшәткәләр белән ишекләр нигә? Әгәр тоткын булсам, минем нинди гаебем бар?

— Сез үзегезгә дип билгеләнгән бүлмәдә утырасыз, ханым. Миңа диңгезгә чыгып сезне каршы алырга һәм шушы замокка алып кайтырга боерык биргәннәр иде. Минемчә, ул боерыкны мин солдат буларак һичбер тайпылусыз һәм дворян буларак илтифат белән үтәдем. Шуның белән минем, һич югы хәзерге вакытта, сезне кайгырту бурычым бетә, моннан аргысы инде башка кешегә кала.

— Башка кеше дигәнегез кем ул? — дип сорады миледи.— Сез аның исемен әйтә алмассызмы?

Шул вакыт баскычта чак-чок итеп шпорлар чыңлаганы, кеше тавышлары ишетелде, аннары бу тавышлар тынып калды, бары тик ишеккә якынлашып килгән берәүнең тып-тып аяк атлаганы гына ишетелде.

— Башка кеше дигәнем әнә ул, ханым,— диде офицер, ишектән бер читкәрәк тайпылды да ихтирамлы бер позада басып катып калды.

Ишек ачылып китеп, ниндидер бер кеше күренде.

Бу кешенең башында эшләпәсе юк, биленә кылыч аскан, кулына тоткан яулыгын селеккәләп кереп килә иде.

Ярым караңгыда басып торган бу кешене миледи таный шикелле тоелды; ул кулы белән кресло култыксасына таянды да таныганлыгына тәгаен ышану өчен алга табарак сузылды.

Әлеге кеше әкрен генә якынлаша башлады, һәм ул лампа яктысына кергән саен, миледи ирексездән креслоның эченәрәк кайшала барды.

Таныш кеше икәнлегенә бернинди шиге калмагач, ул инде тәмам шаккатып кычкырып җибәрде:

— Ничек бу! Сез, абыеммы бу?

— Әйе, гүзәл ханым! Мин булам,— диде лорд Винтер, ярым ихтирамлы итеп, ярым шаяртып баш иеп алды.

— Димәк, бу замок...

— Минеке.

— Бу бүлмә?

— Сезнеке.

— Димәк, мин сезнең әсирегез.

— Шул чама.

— Кабахәт рәвештә көчләү була бит бу!

— Андый каты сүзләр әйтү кирәкми, кара-каршы утырып, абый белән сеңел шикелле, тыныч кына сөйләшик.

Шулай дигәч, ул ишеккә таба борылды да, офицер егетнең боерык көткәнен күреп:

— Яхшы, рәхмәт сезгә! Ә хәзер, Фельтон әфәнде, безнең үзебезне генә калдырып торыгыз инде,— диде.

## XX

## КАЙНАГА БЕЛӘН КИЛЕННЕҢ СӨЙЛӘШҮЛӘРЕ

Лорд Винтер ишекне бикләп, тәрәзә капкачларын япкан һәм урындыгын киленнәренең креслосына табарак күчергән арада, миледи, тирән уйга калып, үзенең бу хәлгә төшүен күңеленнән төрлечә фараз кылып-юрап карады һәм, ниһаять, үзенә каршы яшерен бер ният корганлыкларын төшенде,— үзенең кем кулына килеп эләгүен белгәнче ул мондый нәрсә булырын уена да китерә алмаган иде. Кайнагасы белән танышканнан бирле миледи аның чын дворян, бик һәвәс аучы, комарлы уенчы икәнен, хатын-кыз артыннан өстерәлергә ратса да, интригалар кору сәләте юклыгын белә иде. Милединың Англиягә килүен ничек белеп эләктерде икән ул аны? Нигә ул аны бикләп тота?

Дөрес, Атос сүз арасында гына бер нәрсә ычкындырган иде — шул сүздән миледи үзенең кардинал белән сөйләшүен тыңлап торганлыкларын төшенгән иде, ләкин Атос шулай бик тиз һәм бик кыю төстә шундый эш эшләр дип уена да китерә алмады ул.

Миледи, барыннан да бигрәк, Англиядә моңарчы кылган яман эшләрем калкып чыккандыр, дип шикләнде. Бекингэмның теге ике асылташны миледи кисеп алганлыгын сизенгән һәм шундый вак хыянәте өчен аннан үч алуы ихтимал; ләкин Бекингэм ачудан гына хатын-кызга карата, бигрәк тә асылташларны көнчелектән кисеп алган дип уйласа, андый җәбер эшләмәс.

Милединың хәлне шулай юравы иң дөресе кебек тоелды: ул алда эшлисе эшләрем өчен түгел, элеккеләре өчен үч алырга телиләр дип уйлады. Ничек кенә булмасын, ул, акыллы, чын дошманга килеп капмыйча, кайнагасы кулына гына эләгүенә бик сөенде, чөнки ул моннан шактый ансат котылырга чамалый иде.

— Әйдәгез, сөйләшик соң, кадерле абзам,— диде миледи шактый кәефле бер төс белән. Лорд Винтер никадәр ачылмаска тырышса да, миледи алда ничегрәк эш итү өчен кирәкле булган

бөтен нәрсәне шушы сөйләшүдән белеп-чамалап калырга исәпли иде.

— Димәк, сез, Парижда чакта, моннан ары Бөек Британиягә аягымны да басмаячакмын, дип әллә ничә тапкыр әйтүегезгә карамастан, барыбер Англиягә яңадан килдегез? — дип сүзен башлады лорд Винтер.

Миледи сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды:

— Иң элек сез миңа шуны әйтегез әле: ничек итеп сез минем арттан шундый көчле күзәтү оештырып, минем монда киләсемне генә түгел, хәтта нинди көнне, сәгать ничәдә, кайсы гаваньга киләсемне дә алдан ук белеп тордыгыз?

Лорд Винтер да сөйләшүдә нәкъ миледи ысулын сайлады, киленнәре шул рәвешчә сөйләшкәч, иң яхшысы шулайдыр, дип уйлады.

— Иң элек сез миңа әйтегез әле, кадерле сеңлем, Англиягә ни йомыш белән килдегез? — диде лорд бу сүзгә каршы.

Миледи, үзенең ялган сүзе белән кайнагасында д'Артаньян хатын укыганнан соң туган шикне тагын да көчәйтәсен уйламастан, әңгәмәдәшен үзенә якынайтырга теләп кенә:

— Мин сезне күрергә килдем,— диде.

Лорд Винтер төксе генә чырай белән:

— Шулай укмыни, мине күрергәмени? — дип кайтарып сорады.

— Әйе, әлбәттә, сезне күрергә. Моның нәрсәсе гаҗәп соң?

— Димәк, сез Англиягә мине күрәсегез килеп килгән, башка берниндн максатыгыз булмаган?

— Әйе шул.

— Димәк, сез мине күрер өчен генә үзегезгә шундый зур мәшәкать ясап Ла-Манш аша кичкәнсез?

— Фәкать сезне күрер өчен генә.

— Шайтан алгыры! Шундый яратасыз икән сез мине, сеңлем!

— Ә мин сезнең иң якын туганыгыз түгелмени? — диде миледи бик ихласланган булып.

Лорд Винтер, үз нәүбәтендә, миледига туп-туры текәлеп әйтә куйды:

— Хәтта ки минем бердәнбер варисым, шулаймы?

Миледи, нихәтле бирешмәскә, үзен кулда тотарга тырышса да, ирексездән калтыранып куйды, чөнки лорд Винтер әлеге сүзен әйткәндә кулын киленнәренең иңбашына куйды һәм ханымның калтырануын искәрми калмады.

Чыннан да, бик урынлы туры килеп, шактый үткәзерлек булды бу. Милединың күңеленә килгән беренче уе: «Мине Кэтти саткан, камеристкам алдында, саксызланып, баронны үземә мираска каласы байлыгы аркасында яратмавымны сөйләгән идем, Кэтти шуны баронга әйткән», дигән уй булды; шулай ук д'Артаньян аның кайнагасын исән калдырганнан соң, миледи үзенең, саксызланып, д'Артаньянга ябырылуын да исенә төшерде.

Беркадәр вакыт отып, дошманын сөйләтү өчен, ул:

— Мин сезнең ни әйтергә теләгәнегезне аңламыйм, милорд! Сезнең әйткән сүзегездә берәр яшерен мәгънә юкмы? — диде.

— Юк, әлбәттә, юк,— диде лорд Винтер ягымлыланган булып.— Сез мине күрергә теләгәнсез дә Англиягә килгәнсез. Мин сезнең шундый теләгегез барлыгын белеп, дөресрәге — шуны сизеп, сезне төнлә портка килеп төшү мәшәкатьләреннән коткару өчен бер офицерымны каршы алырга җибәрәм. Мин аңа карета бирәм, ул сезне мин комендант булып көн саен килеп йөргән шушы замокка алып кайта һәм, безгә бер-беребезне күреп сөйләшергә мөмкинлек булсын дип, мин аңа сезнең өчен бүлмә әзерләп куярга кушам. Болар сез үзегез миңа әйткәннән гаҗәбрәк булып тоеламыни?

— Юк, миңа сезнең минем килүем турында алдан белеп торуыгыз гаҗәп.

— Ә монысының сәбәбе бик гади, кадерле сеңлем: корабыгызның капитаны, рейдка туктаганчы, портка керергә рөхсәт алу өчен, алдан судно журналы, команда һәм пассажирлар исемлеге белән кечерәк бер көймә җибәргәнен күрмәдегезмени? Мин — порт башлыгы, исемлекне китергәч, анда сезнең исемегезне күрдем. Сез менә хәзер үз телегез белән әйткәнне минем күңелем сизде: диңгездә йөзү бик кыенлашкан бер вакытта, хәвеф-хәтәр булуыннан курыкмыйча, нинди сәбәп белән юлга чыгуыгызны сизендем дә сезне каршы алырга үземнең куттерны җибәрдем. Калганы инде мәгълүм сезгә.

Миледи, лорд Винтерның ялган сөйләвен төшенеп, тагы да катырак курка башлады.

— Кадерле абзам,— дип яңадан сүзгә кереште ул,— бүген кич гаваньга кергән чакта молда күргән кешем милорд Бекингэм түгел идеме?

— Әйе, ул. Ә, аңлыйм, сез аны күргәч дулкынлангансыз: сез килгән илдә бөтен кеше аны уйлап борчыла бугай, аның Франция белән сугышка әзерләнүе сезнең дустыгыз кардиналны бик борчыганын да беләм мин.

— Кардинал — минем дустым?! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды миледи, лорд Винтерның бу мәсьәләдә дә шактый мәгълүматлы булуына тагы да ышана төште.

— Нигә, сезнең дустыгыз түгелмени ул? — диде барон, исе китмәгән шикелле генә.— Ялгышкан булсам, гафу итегез: миңа шулайдыр кебек тоелган иде. Ярый, милорд герцог мәсьәләсенә соңрак әйләнеп кайтырбыз, хәзергә әңгәмәбездәге ихлас тойгылы юнәлешебездән читкә тайпылмыйк: сез бит мине күрергә теләп килдем дигән идегез?

— Әйе.

— Ярый алайса! Мин сезгә әйттем инде: һәммәсе сезнең теләккә ярашлы итеп җайланды, без сезнең белән көн саен күрешә алачакбыз.

— Нәрсә, мин монда мәңгегә калырга тиешме инде? — дип куркуга төшкән бер тавыш белән сорады миледи.

— Сезнең өчен монда, бәлки, кайбер җайсызлыклар бардыр, сеңлем? Ул чагында ниләр житешмәгәнен әйтегез, мин аларны эшләтермен.

— Минем асрауларым да, хезмәтчеләрем дә юк.

— Барысы да булыр, ханым. Әйтегез әле: беренче ирегез белән торганда сезнең йортыгызда тормышыгыз ничегрәк иде? Мин сезнең кайнанагыз гына булсам да, монда да нәкъ шундый итеп эшләтермен.

Миледи, лорд Винтерга аптырашлы бер караш белән текәлеп:

— Минем беренче ирем?! — дип кычкыра төшеп сорады.

— Әйе, сезнең француз ирегез, үземнең туганым турында әйтмим мин... Хәер, әгәр сез аны оныткан булсагыз, ул исән әле, мин аңа хат яза алам, миңа кирәкле барлык мәгълүматларны язып җибәрер ул.

Милединың маңгаена салкын тир бәреп чыкты.

— Шаяртасыз сез,— дип басынкы бер тавыш белән генә әйтеп куйды ул.

Барон, торып, бер адым арткарак чикте дә:

— Минем кыяфәтем шундыймыни? — диде.

— Яки, дөресрәге, сез мине мыскыл итәсез,— дип сүзендә дәвам итте миледи; калтырана-калтырана бармакларын кресло култыксаларына батырды да урыныннан күтәрелә төште.

— Мин сезне мыскыл итәм?! — диде лорд Винтер көлеп.— Ханым, сезне мыскыл итү мөмкин дип уйлыйсызмы?

— Сез, галиҗәнап, я исерек, я акылдан язгансыз,— диде миледи.— Чыгып китегез моннан, миңа булышырга берәр хатын-кыз җибәрегез.

— Хатын-кыз ул сер саклый алмый, сеңлем! Үзем генә камеристкагыз булыйм! Шуннан сезнең гаилә серләрегез безнең ике арада гына калыр.

— Оятсыз! — дип кычкырып җибәрде миледи, пружинадан атылган кебек, баронга таба талпынып куйды. Барон бу вакытта кулларын аска төшереп кушырыбрак тора, шулай да бер кулын кылыч сабына куйган иде.

— Әһә! — дип куйды ул.— Мин сезнең кеше үтерү гадәтегез барлыгын беләм, ләкин искәртеп куям: минем сездән дә кылыч белән саклануым ихтимал.

— О, хак әйтәсез, сезнең хатын-кызга каршы кул күтәрергә дә намусыгыз җитәдер.

— Әйе, бик ихтимал. Моның өстенә, минем акланырлык сәбәбем дә бар: минем кулым сезгә каршы күтәрелгән беренче ир кеше кулы булмас дип беләм.

Шулай дигәч, барон, миледины гаепләгән шикелле, кулын җайга гына сузып, аның сул иңбашына бармагын тидерә язып төртеп күрсәтте.

Миледи, ырылдаган кебек, буылып аһылдап куйды да, сикерергә җыенган юлбарыс сыман, бүлмәнең аргы почмагына таба чигенде.

— Теләгән кадәр ырылдагыз! — дип кычкырды лорд Винтер.— Ләкин тешләргә маташмагыз, чөнки кисәтеп куям — сезнең өчен андый эшнең азагы бик яман булыр; монда алдан ук варислык хокукларын билгеләп куючы прокурорлар да, шундый чибәр ханымны тоткынлыкка төшергән өчен мине кылыч белән сугышырга чакыручы мөсафир рыцарь да юк, әмма минем әзерләп куйган судьяларым бар — әгәр кирәк булса, алар, ире исән була торып, минем туганым лорд Винтер түшәгенә үрмәләгән оятсыз хатынны бик каты хөкем итәрләр һәм, кисәтеп әйтәм, сезне палач кулына тапшырып, ике кулбашыгызны да тамгалы иттерерләр.

Милединың күзендә шундый яшен утлары уйный — лорд Винтер, ир кеше булса да һәм коралсыз хатын алдында корал белән басып торса да, йөрәгенә курку керә башлаганын тойды. Шулай да ачу-ярсуы кайнап сөйли бирде:

— Әйе, аңлыйм, туганым үлеп, аның мирасына тиенгәннән соң, минем мөлкәтне алу да сезгә бик күңелле булган булыр иде. Тик белеп торыгыз: сезнең мине үтерүегез яки кеше яллап үтертүегез ихтимал,— шуңа күрә мин алдан ук моның чарасын күреп куйдым: минем байлыгымның бер пенние дә сезнең кулга кермәячәк. Миллионлап байлыгыгыз була торып, шул җитмәгәнмени сезгә? Явызлык кылуны җаныгыз теләгәнгә генә эшлисез икән, сезгә ул һәлакәтле юлыгыздан тукталырга вакыт түгел микән? Ихластыр: минем өчен туганымның истәлеге изге булмаса, мин сезне берәр дәүләт төрмәсендә черетер яисә халыкка тамаша ясарга Тайбернга * озатыр идем. Мин сезнең хакта беркемгә әйтмәячәкмен, әмма сез дә тоткынлыкта тыныч кына ятарга тиешсез. Бер унбиш-егерме көннән мин армия белән Ларошельгә китәм, ләкин мин китәргә бер көн кала кораб килеп, минем күз алдымда сезне көньяктагы колонияләребезгә алып китәр; мин сезгә кеше ияртеп җибәрәм, шуңа күрә бер дә борчылмагыз: ул сезнең Англиягә яисә материкка кайтырга дип беренче тапкыр маташуыгызда ук маңгаегызга пуля җибәрәчәк.

Миледи бик игътибар белән тыңлап торды, күзләре ялт-йолт итеп, күз каралары зураеп-зураеп китте.

— Әйе, хәзер сез шушы замокта яшиячәксез,— дип сүзендә дәвам итте лорд Винтер.— Моның стеналары калын, ишекләре авыр, тәрәзә рәшәткәләре нык; өстәвенә, сезнең тәрәзә нәкъ диңгез турысында. Минем экипажның кешеләре миңа бик турылыклы, шушы бүлмә каршысында сакта торалар, ишегалдына керә торган бөтен юлларны саклыйлар; сез анда чыга алсагыз да, сезгә тагын өч кат тимер рәшәткә аша узарга туры килер иде. Бик каты итеп әмер бирелде: качарга ниятләвегезне белдергән бер генә адымыгыз, бер генә хәрәкәтегез, бер генә сүзегез сизелсә дә,— сезгә атачаклар; әгәр сезне шунда үтерсәләр, Англия суды үзен бер мәшәкатьтән коткарган өчен миңа рәхмәт

---

* Иске Лондонның бер кварталы, шунда бөтен халык алдында гаепле кешене җәзалаганнар. *(ред. искәрмәсе).*

кенә әйтер дип уйлыйм. Ә! Йөзегезгә элеккечә сабырлык һәм үз-үзегезгә ышанганлык галәмәте чыкты; сез эчегездән генә уйлыйсыз: «Унбиш-егерме көн... Ярый, минем зиһенем җитәрлек, ул вакытка хәтле бер-бер нәрсә уйлап табармын! — дисез.— Мин яман да акыллы, үземә берәр корбан табармын. Унбиш көннән инде мин монда булмам»,— дисез. Ярый алайса, тырышып карагыз!

Миледи, лорд Винтерның аның күңелендәге уйларны чамалавын күреп, тырнакларын уч төбенә батырды — моның белән ул, күңелендәге кичерешләрен чыраена чыгармаска теләп, йөзендә кайгырган-борчылган бер төс кенә сакларга тырышты.

Лорд Винтер сөйләвендә дәвам итте:

— Биредә мин югында башлык булып калачак офицерны сез күрдегез инде, димәк, сез аны беләсез; күргәнегезчә, кушкан боерыкны җиренә җиткереп үти белә: Портсмуттан бирегә кайткан чакта сез, әлбәттә,— мин сезне беләм инде,— аны сөйләштерергә тырышып карагансыздыр. Я, нәрсә диярсез соң? Мәрмәр статуя аңардан сүзсез һәм хиссезрәк була алыр микән? Сез инде үзегезнең чибәрлегегезне бик күп кеше каршында сынап караганыгыз бар һәм, бәхетсезлеккә каршы, гел уңышка ирешә килдегез. Сез аны менә бу кеше каршында сынап карагыз, максатыгызга ирешә алсагыз, мин сезне, шайтан алгыры, шуннан соң чын иблис дип санаячакмын!

Лорд Винтер ишек янына китеп, аны җәһәт кенә ачып җибәрде дә:

— Фельтон әфәндене минем янга чакырыгыз әле! — дип боерык бирде, аннары миледига таба борылып: — Хәзер мин аны сезнең белән таныштырам,— диде.

Шуннан соң бу ике кеше арасында сәер бер тынлык урнашты; шул тынлыкта бүлмәгә таба әкрен генә, салмак кына атлап килгән аяк тавышы ишетелде. Озакламый ярым караңгы коридорда кеше гәүдәсе шәйләнә башлады һәм безгә таныш офицер егет, баронның ни боерганын көтеп, бусагада туктап калды.

— Керегез, Джон дустым, керегез дә ишекне ябыгыз,— диде лорд Винтер.

Офицер бүлмәгә керде.

— Ә хәзер менә бу хатынга карагыз,— дип сүзендә дәвам итте барон,— ул яшь, бик чибәр, ирләрне кызыктыра торган бөтен сыйфатлары бар. Әмма шулай да нинди диген! Нибары егерме биш яшендәге шушы явыз хатын үз гомерендә шул хәтле күп җинаять кылган — безнең судларның берьеллык архивларыннан да ул хәтлене җыя алмассыз. Аның тавышы бик ягымлы, матурлыгын корбанына җим итә, тәне — вәгъдә иткәнне бирә,— бу яктан аны мактамаслык түгел. Ул сезнең күңелегезгә вәсвәсә салырга тырышыр, хәтта үтерүе дә ихтимал. Мин сезне фәкыйрьлектән коткардым, сезгә лейтенант чины бирдем, бервакыт үзегезне үлемнән коткарып калдым — ничек булганын хәтерлисездер,— мин сезнең химаячегез генә түгел, бәлки, дустыгыз, сезгә яхшылык итүче генә түгел, бәлки, атагыз мин сезнең.

Бу хатын Англиягә мине үтерү нияте белән кайткан. Бу юха еланны мин үз кулымда тотам. Сезне чакырып, мин шуны бик үтенәм: дустым Фельтон, Джон, балам, бу хатыннан мине саклый күр, бигрәк тә үзең саклана күр. Үзенә тиешле җәзасын алганчы мин аны саклармын дип ходай исеме белән ант ит. Джон Фельтон, мин синең вәгъдәңә ышанам! Джон Фельтон, мин синең намусыңа ышанам!

— Милорд, ант итеп әйтәм, бөтенесе нәкъ сез теләгәнчә эшләнер,— диде офицер егет, күңелендә булган бөтен нәфрәтен туплап, миледига карап алды.

Миледи бу карашка юаш бер корбан кыяфәте белән генә җавап кайтарды, аның чибәр йөзендәге кебек тагы да юашрак, мәхлуграк төс булыр дип күз алдына да китерүе мөмкин түгел иде. Лорд Винтер аны үзе дә кылыч белән каршы торырга җыенган әлеге ана юлбарыс дип уена да китермәс иде.

— Бу бүлмәдән чыгарга тиеш түгел ул, ишетәсеңме, Джон,— диде лорд Винтер,— ул беркем белән хат язышырга, беркем белән сөйләшергә тиеш түгел, кирәк тапсагыз, сез генә сөйләшә аласыз.

— Мин ант итеп әйттем бит инде, милорд, шул җиткән.

— Хәзер инде, ханым, язмышыгызга күнеп, ходайның ризалыгын алырга тырышыгыз, чөнки кешеләр сезгә хөкем чыгарды инде.

Миледи, бу хөкемне күтәрә алмагандай, башын аска иде.

Лорд Винтер кулы белән ишарәләп кенә Фельтонны үзе артыннан иярергә чакырды да бүлмәдән чыгып китте, Фельтон да, аның артыннан чыгып, ишекне бикләде.

Беравыктан диңгез пехотасы солдатының авыр-авыр басып коридорда йөргәне ишетелде. Ул, биленә айбалта асып, кулына мушкет тотып, ишек төбенә сакка баскан иде.

Миледи, йозак тишегеннән үзен күзәтеп торалардыр дип, берничә минут баягы рәвешен үзгәртмичә утырды; аннары әкрен генә башын күтәрде һәм йөзенә яңадан куркыткан, янаган төс чыкты. Тиз генә ишек төбенә килеп, тыңлап торды, аннары тәрәзәгә барып күз салды, шуннан соң инде тәрәзә яныннан китеп, дәү креслога утырды да уйга калды.

## *XXI*

## *ОФИЦЕР*

Бу вакытта исә кардинал Англиядән хәбәрләр көтә, ләкин күңелсез һәм куркыныч хәбәрләрдән башка берниндм яңалык килми иде.

Ларошель бик тыгыз камап алынган булса да, күрелгән чаралар нәтиҗәсендә, бигрәк тә камалудагы шәһәргә көймәләр үтәргә комачаулаучы дамба аркасында бу камауның уңышлы икәнлеге бик ачык күренеп торса да, блокада әле тагын бик озакка сузылачак, бу хәл король гаскәрләре өчен зур хурлык

булачак, ә кардиналда исә зур канәгатьсезлек тудырачак иде. Дөрес, кардиналга хәзер Людовик XIII не Анна Австрияле белән талаштырырга кирәкми, чөнки бу эш инде эшләнгән, хәзер герцог Ангулемлы белән низаглашкан Бассомпьер әфәндене татулаштырасы бар иде.

Корольнең энесенә килгәндә, ул әле камауны яңа башлаган гына, аны башкарып чыгу мәшәкатен исә кардиналга калдырган иде.

Мэрның гаять нык торуына да карамастан, шәһәр, дошманга бирелергә ниятләп, баш күтәрмәкче булып та карады, әмма мэр фетнәчеләрне тотып асарга әмер бирде. Мондый каты җәза иң ярсу йөрәклеләрне дә тынычландырды, шуңа күрә алар ачлык газабы кичерергә карар иттеләр: ни дисәң дә, болай үлү дар агачына асылып үлүгә караганда бик тиз һәм тәгаен булмас кебек тоелды аларга.

Каланы камап торучылар ара-тирә ларошельлеләрнең Бекингэмга җибәргән йомышчыларын яисә Бекингэмның ларошельлеләргә җибәргән шымчыларын эләктергәлиләр. Тегесендә дә, бусында да хөкем бик кыска була, кардинал: «Асарга!» — дип бер генә сүз әйтә. Боларны асканны карарга корольне дә чакыралар. Король сүлпән генә атлап килә дә бу тамашаны бөтен вагы-төягенә хәтле күрер өчен җайлырак урынга урнаша. Ләкин моңа карап кына аның бик каты эч пошуы басылмый, минут саен: «Парижга кайтып китәм»,— дип сөйләнүеннән дә туктамый, шулай да бу тамаша беркадәр аның күңелен күтәреп җибәрә, камауга сабырлыгын җыя төшебрәк түзәргә мәҗбүр итә. Болар кулына әнә шул йомышчылар белән шымчылар эләккәләп тормаса, кардинал хәзрәтләре, никадәр зирәк һәм тапкыр акыллы бер кеше булса да, шактый кыен хәлдә калган булыр иде.

Ләкин көн артыннан көн уза тора, ларошельлеләрнең дә бирелергә исәпләре юк иде; камап торучыларга килеп эләккән соңгы йомышчыда Бекингэм исеменә атап язылган хат бар иде. Дөрес, хатта каланың соңгы чиккә җитүен әйтсәләр дә, азагында: «Әгәр ике атна эчендә сездән ярдәм килеп җитмәсә, без биреләбез»,— димәгәннәр, бәлки, гади генә итеп: «Әгәр ике атна эчендә сездән ярдәм килеп җитмәсә, ярдәм килгән вакытка без инде барыбыз да ачтан үлеп беткән булырбыз»,— дип язганнар иде.

Шулай итеп, ларошельлеләрнең бөтен өмет-ышанычлары Бекингэмда гына иде. Бекингэм алар өчен бер кодрәт иясе иде. Моннан ары Бекингэмга исәп тотасы юклыгын тәгаен белсәләр, аларның өмет белән бергә рухларын да җуячаклары билгеле иде.

Шуңа күрә кардинал, бик түземсезләнеп, Бекингэмның Ларошель янына килмәячәге турында Англиядән хәбәр көтә иде.

Каланы һөҗүм итеп басып алу мәсьәләсе, король киңәшмәсендә еш каралса да, гел кире кагыла килде: беренчедән,

Ларошельне алай гына алып булмас кебек тоела, икенчедән, кардинал, нәрсә дип кенә сөйләсә дә, французларның французларга каршы сугышып кан коюлары политикада алтмыш елга артка чигенү булачагын бик яхшы аңлый, ә ул, хәзерге көндә әйткәнчә, үз заманының алдынгы бер кешесе була. Чыннан да, Ларошельне тар-мар китереп, өч-дүрт мең һугенотны үтереп ташлау (ә алар үлсәләр дә бирелмәячәкләр) 1628 елда 1572 елның Варфоломей төненә охшап калыр иде; аннары бу инде иң соңгы бер чара иде, король католик җанлы кеше буларак мондый эшне өнәмәгәнлеген сиздерми, тик камаучы генераллар гына, Ларошельне фәкать ачлык белән генә алырга мөмкин дип, һаман кире кагып киләләр иде.

Кардинал үзенең хәтәр йомышчысы турында уйлаган саен күңеленә ирексездән шик-шом керә,— бу хатынның сәер сыйфатларын ул да сизенгән, бу хатын аңа әле юха елан, әле усал арслан булып тоела иде. Йомышчы хатыны аңа хыянәт итмәдеме икән? Әллә үлгәнме? Һәрхәлдә, кардинал инде аның нindилеген ярыйсы ук белде: миледи аның файдасына яки аңа каршы эшлиме, аңа дус яки дошманмы — барыбер берәр зур комачаулык килеп чыкмаса, беркайчан да үз эшен эшләми тормый. Тик андый комачаулык каян килеп чыксын икән? Менә монысын инде кардинал белми иде.

Хәер, ул миледига нык ышана, чөнки ышанырлык нигезе дә бар: бу хатынның узган гомер юлында коточкыч нәрсәләр барлыгын ул сизенә, аларны фәкать кардиналның кызыл мантиясе генә каплый ала, шуңа күрә теге яки бу сәбәптәнме аның кардинал ягында булуын сизеп тора, чөнки миледины төрле куркынычтан кардинал гына саклап кала һәм ярдәм итә ала иде.

Шулай итеп, кардинал сугышны бер үзе генә дәвам иттерергә һәм читтән килеп чыгардай ярдәмне очраклы бер бәхет дип кенә көтәргә карар итте. Ларошель халкын ачтан үтерергә тиешле атаклы дамбаны өйдерүендә дәвам итте; шул хәлне көтеп, күпме газап-михнәт күргән, күпме батырлык күрсәткән бу мескен кала өстенә карап торган чагында ул үзенең сәяси элгәре Людовик XI нең сүзләрен, химаяче Тристанның*: «Хакимлек итәсең килсә — бүлгәлә»,— дигән кагыйдәсен исенә төшерде.

Һенрих IV, Парижны камап алгач, стена аша икмәк һәм башка ашамлыклар ташларга кушкан; кардинал исә Ларошель кешеләренә башлыкларының, үз максатларыннан гына чыгып, гаделсез һәм рәхим-шәфкатьсез эш итүләрен аңлата торган хатлар ташларга кушты. Ул башлыкларның икмәге бик күп икән, тик аны халыкка өләшмиләр генә икән; алар «хатын-кыз, карт-коры, бала-чага ачтан үлсә үлсен, тик каланың стеналарын саклаучы ирләр генә сау булсын» дигән кагыйдәдән чыгып

* Тристан — Людовик XI заманындагы (XV гасыр) дәүләт эшлеклесе.

(аларның да үз кагыйдәләре булган) эш итәләр, имеш. Ул вакытка бу кагыйдә гомум күләмдә кулланылмаса да, халыкның моңа каршы торырлык көче булмагангамы, әллә үз-үзләрен корбан иткәнгәме, теориядән практикага әйләнә. Кардинал ташлаткан хатлар бу кагыйдәнең дөреслегенә ышанычны бетерде; бу хатлар ач үлемгә дучар ителгән бала-чага, хатын-кыз, карт-коры ирләрнең ул-кызлары, хатыннары, эти-әниләре икәнлеген исләренә төшерде, уртак бәла бөтен кеше өчен дә уртак булсын иде, шул чагында бер үк хәлгә төшкән халык карары да бер төрле булыр иде дигән фикер уятты.

Ташландык хатлар нәкъ аларны яздырган кеше көткән нәтиҗәне бирде: байтак кешене король армиясе белән сепарат сөйләшүләр башларга кирәк дигән фикергә китерде.

Ләкин кардинал әнә шулай, бу сыналган чарасының нәтиҗәләрен күреп, моны эшкә кушуына бик сөенеп торганда король гаскәрләре линиясеннән үткән бер Ларошель кешесе,— бу линиядән ничек үтә алгандыр,— анысын бер ходай гына белә, чөнки Бассомпьер, Шомберг һәм герцог Ангулемлылар ул линияне бик уяу саклыйлар, үз нәүбәтендә аларны кардинал да бик уяу күзәтеп тора иде,— әйткәнебезчә, Ларошельнең бер кешесе туп-туры Портсмуттан килеп, калага үтте дә: «Мин анда бер атнадан да соңгармыйча кузгалырга әзер торган бик зур флот күрдем»,— диде. Алай гына да түгел, Бекингэм мәрга, ниһаять, Франциягә каршы бөек союз төзеләчәген һәм Франция корольлегенә берьюлы инглиз, империя һәм испан гаскәрләре бәреп керәчәген әйтеп хат язган. Бу хатны шәһәрнең бөтен мәйданнарында халыкка кычкырып укыйлар, күчермәләрен урам чатларына ябыштырып чыкканнар, хәтта король армиясе белән сөйләшүгә керешкән кешеләр дә, сөйләшүдән туктап, бик тантаналы итеп ышандырган ярдәмнең килгәнен көтәргә карар кылганнар икән.

Бер дә көтелмәгән бу хәл Ришельеның элекке борчуларын яңадан кузгатты һәм аны ирексездән тагын диңгез аръягына өмет багларга мәҗбүр итте.

Үзенең бердәнбер һәм чын башлыгының кайгы-борчуларын бөтенләй белмәгән король армиясе исә бу вакытта бик күңелле итеп яшәп ята; лагерьда азык-төлек тә, акча да җитәрлек; частьлар егетлек-чаялыкта һәм төрлечә күңел ачуда бер-берсен уздырырга тырышып ярышалар. Шпионнарны тотып асалар, дамбага һәм диңгезгә хәтәр экспедицияләр оештыралар, әллә нинди акылсыз эшләргә керешеп, шуны бик салкын кан белән башкарып чыгалар — армия үзенең вакытын әнә шундый шөгыльләре белән үткәрә һәм болар ачлык газабы кичереп, ярдәм көтеп интеккән Ларошель кешеләре өчен генә түгел, бәлки, аларны зур тырышлык белән камап торучы кардиналга да озын-озак булып тоелган көннәрне уздырып җибәрергә ярдәм итә иде.

Кардинал, гел гади кавалерист шикелле атка атланып кына йөрергә чыккач, бик акрын эшләнгән сыман тоелган ныгытма-

ларны уйчан гына бер кыяфәттә күзеннән кичерә,— Франциянең барлык төбәкләреннән китерткән инженерлар аның җитәкчелегендә шул ныгытмаларны коралар; әнә шулай карап-тикшереп йөргән чагында де Тревиль полкыннан берәр мушкетер очраса, кайвакыт ул шуның янынарак килеп текәлебрәк карый, бу мушкетер безнең дүрт дусның берсе дә түгел икәнлеген белгәч инде, үткен карашы белән тирән акылын башка нәрсәгә юнәлтә.

Беркөнне кардинал, шәһәр белән сөйләшүгә бүтән өмете калмавына һәм Англиядән һаман да бернинди хәбәр килмәвенә бик яман эче пошып, Каюзак белән Ла Удиньерны гына ияртеп, һичбер максатсыз, атта йөреп кайту өчен генә, өеннән чыгып китте; иксез-чиксез хыялларына бирелеп һәм иксез-чиксез диңгез өстен күзеннән кичерә-кичерә, комлы яр чите буйлап узды; ашыкмыйча гына калку җир өстенә менгәч, үзләреннән бераз арырак киртә артында җиде кеше күрде. Бу кешеләр елның шушы вакытында болыт астыннан бик сирәк күренгәләгән кояш җылысында җылынып яталар, яннарында буш шәраб шешәләре аунап ята иде. Бу җиде кешенең дүртесе безнең мушкетерлар булып, әле яңа гына берәүсенә килгән хатны тыңларга җыенып торалар иде. Бик мөһим хат иде бу, шуның өчен алар барабан өстенә таратып салган карта һәм шакмакларын да калдырып торганнар.

Җиденең калган өчесе салам үрмәсе белән тышлаган бик дәү колиур шәрабы шешәсенең муенындагы сумаланы кубарып маташа; болары инде безнең егетләрнең хезмәтчеләре иде.

Әйткәнебезчә, кардиналның кәефе бик начар чак иде, ә андый чакта исә башкаларның кәеф-сафа корып ятуларын күрсә, аның чырае тагы да караңгыланып китә иде. Өстәвенә тагын, бик сәер бер гадәте дә бар иде: башкалар нәкъ аны борчыган нәрсәләрдән рәхәт табып кәефләнәләрдер кебек тоела иде кардиналга. Ул Каюзак белән Ла Удиньерга туктагыз дип ишарә итте дә үзе, атыннан төшеп, әлеге шикле егетләргә таба китте — комда аяк тавышым ишетелмәс, киртә ышыгыннан мине күрмәсләр дип, ул тегеләрнең бик кызыклы булырга тиешле әңгәмәләрен бераз ишетеп калмаммы дип өметләнә иде; киртәгә ун адым чамасы гына калгач, кардинал Гасконь егетенең тавышын таныды, боларның мушкетер егетләр икәнлеген моңарчы ук таныганлыктан, калган өчесе теге аерылгысыз дуслар, ягъни Атос, Портос һәм Арамис булуларына бер дә шикләнмәде.

Мондый ачышыннан соң егетләрнең ни сөйләшкәнен бик ишетәсе килүе үзеннән-үзе аңлашылып тора иде: күзләре аның әсәрләнеп сәер бер кыяфәткә керде. Үзе мәче шикелле шыпырт кына атлап киртә янынарак барды. Ләкин мәгънәсе ачык аңлашылмаган берничә аваз ишетү белән кинәт кемдер каты гына кычкырып куеп кардиналны сискәндереп җибәрде, мушкетерларның игътибарын җәлеп итте.

— Офицер! — дип кычкырды Гримо.

Атос, терсәгенә таянып күтәрелә-күтәрелә, Гримога ачу белән карады да:

— Сөйләшәсең түгелме син, җүнсез! — диде.

Шуннан соң Гримо бер сүз эндәшмәде, кардинал белән аның яраннары килгәнлеген белгертеп, бармагы белән киртә ягына таба төртеп кенә күрсәтте.

Мушкетерлар ялт кына аякларына бастылар да ихтирам белән баш иделәр.

Кардиналның бик яман ачуы килде, күрәсең.

— Мушкетер әфәнделәр үзләрен саклап торырга кушалар, ахры! — диде ул.— Әллә инглизләр коры юлдан киләме, я булмаса мушкетерлар үзләрен өлкән офицер дип саныйлармы?

— Галиҗәнап,— дип җавап бирергә керешге Атос, каушап калган башкалар арасында ул чын вельможага хас сабырлык белән салкын канлылыгын бу юлы да югалтмаган иде,— галиҗәнап, мушкетерлар хәрби хезмәт вазифасын үтәмәгәндә яки ул вазифаны үтәгәннән соң, шәраб эчеп, шакмак уйныйлар һәм үзләренең хезмәтчеләре өчен бик югары дәрәҗәле офицер булып саналалар.

— Хезмәтчеләре! — дип куйды кардинал.— Яннарыннан берәр кеше узса, хуҗаларын искәртергә тиешле хезмәтчеләр хезмәтче түгел, сакчы алар.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, үзегез күреп торасыз бит, әгәр без андый саклык чарасы күрмәсәк, сезгә булган ихтирамыбызны, үзебезгә карата кылган яхшылыгыгыз өчен, безне барыбызны бергә җыйганыгыз өчен рәхмәтебезне белдерү җаен ычкындырган булыр идек...— дип сүзендә дәвам итте Атос.— Д'Артаньян, сез әле генә галиҗәнапка үзегезнең рәхмәтегезне белгертү өчен җай туры китерергә теләвегезне әйткән идегез: менә җае килеп чыкты, файдаланып калыгыз.

Бу сүзләрен Атос хәтәр минутларда да күрсәтә торган сабыр салкын канлылык белән һәм кайчакларда тумышларыннан король булучыларга караганда да үзен мәһабәтрәк король итә торган зур бер әдәплелек белән әйтте.

Д'Артаньян якынрак килде дә мыдырданып берничә сүз белән генә рәхмәтен әйтте, кардиналның төксе карашы астында бу сүзләре бик тиз йомылып та калды.

Атосның әлеге сүзе Ришельеның баштагы ниятеннән аз гына да кире чигермәде, ахры.

— Барыбер, әфәнделәр, гади солдатларның дәрәҗәле частьта хезмәт итүләренә карап кына зур вельможа булып кыланууларын яратмыйм мин: алар да башкалар кебек үк тәртип сакларга тиешләр,— диде ул.

Атос кардиналның шушы сүзен әйтеп бетергәнен көтте дә, килешүен белдереп баш игәч, болай дип җавап кайтарды:

— Галиҗәнап, без берничек тә тәртип бозмадык дип беләм мин. Без хәзер хәрби хезмәт вазифабызны үтәмибез, хезмәттән азат булгач, вакытыбызны үзебез теләгәнчә үткәрә алабыз, дип уйлаган идек. Әгәр сез, галиҗәнап хәзрәтләре, безгә берәр төрле

махсус боерык биреп безне бәхетле итәргә теләсәгез, без сезнең боерыгыгызны үтәргә әзербез. Галиҗәнап, менә үзегез дә күрәсез,— диде мушкетер кашларын җыерып, чөнки кардиналның болай сорау алуы Атосның сабырлыгын төкәндерә башлаган иде инде,— чак кына тревога ишетелүгә дә әзер булып тору өчен без үзебез белән кораллар да алдык,— дип, Атос кардиналга өстенә карталар һәм шакмаклар таратып салынган барабан янына берсе-берсенә терәп бастырып куелган мушкетны бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Галиҗәнап хәзрәтләре, сүзебезгә ышаныгыз: әгәр сезнең бик аз санлы свита белән бирегә киләсегезне белгән булсак, без сезнең каршыгызга ук чыккан булыр идек,— дип өстәде д'Артаньян.

Кардинал мыегын һәм иреннәрен тешләштергәләде.

— Сез менә хәзер барыгыз бергә, кораллы килеш, хезмәтчеләрегез саклап торган чакта, беләсезме кемнәргә охшыйсыз? Дүрт заговорчыга охшыйсыз сез,— диде кардинал.

— Бик дөрес, галиҗәнап,— диде Атос аның сүзен җөпләп,— беркөнне иртән, галиҗәнап хәзрәтләре, үзегез дә күреп ышанган идегез бит, без, чыннан да, заговор корабыз, тик без аны Ларошель кешеләренә каршы корабыз.

— Әй, галиҗәнап политиклар! — диде кардинал бу сүзгә каршы, үз нәүбәтендә кашын җыерып.— Сезнең миләрегездә ни барын әле генә үзегез укыган хат шикелле үк ансат кына укып булса икән, аннан бик күп серләрнең очын табып булыр иде! Мин килгәнне күргәч, билгеле, ул хатны тиз генә яшердегез сез!

Атосның йөзе кызарынып китте, ул кардиналга таба бер адым атлап куйды.

— Галиҗәнап, сез, чыннан да, бездән шикләнәсез, чын мәгънәсендә бездән сорау аласыз дип уйларлык. Алай булганда, галиҗәнап хәзрәтләре, сез безгә рәхим итеп аңлатып бирегез, без аннары, һич югы, ничегрәк эш итәргә кирәклеген белеп торырбыз.

— Әгәр бу чыннан да сорау алу булса, ни әйтерсез, я? — диде кардинал бу сүзгә каршы.— Сез генә түгел, сездән зурраклардан да сорау алып җавап бирдерттек без, мушкетер әфәнде.

— Менә шуңа күрә дә сез галиҗәнап хәзрәтләренә әйттем бит мин: сез бездән сорау алырга теләсәгез, без җавап бирергә әзер дидем.

— Арамис әфәнде, сез бер хат укый башлаган идегез дә аны яшердегез. Нинди хат иде ул?

— Бер хатын-кыз язган аны, галиҗәнап.

— О, аңлыйм,— диде кардинал,— андый хатны сөйләмәү хәерле. Әмма ул хатны изге атага күрсәтергә мөмкин бит; үзегезгә мәгълүм: мин бит изге ата дәрәҗәсе алган кеше.

— Галиҗәнап,— дип сабыр гына сүзгә кереште Атос, әмма бу рәвешле җавап кайтарып ул үзенең башын харап итүе дә

бик ихтимал иде,— ул хатны хатын-кыз язган, ләкин аңа Марион Делорм да, д'Эгильон ханым да кул куймаган.

Кардинал үлек төсле агарынып китте, күзләрендә дәһшәтле-усал чаткылар ялтырады; ул, Каюзак белән Ла Удиньерга нидер боерырга җыенган шикелле, аларга таба борылды. Атос бу хәрәкәтне күреп алды да мушкетларга таба атлап куйды. Үзләрен кулга алдырырга ниятләмәгән өч дустының да күзләре мушкетларга төбәлгән иде. Кардинал ягында үзе белән нибары өч кенә кеше, мушкетёрлар исә хезмәтчеләре белән җидәү иделәр. Атос белән иптәшләре, чыннан да, яшерен рәвештә ни турындадыр сүз берләштергәннәр, шуңа күрә көрәш тиң булмас, дип уйлады кардинал һәм һәрвакыт әзер тота торган хәйләсен — хәлне кисәк кенә үзгәртеп җибәрү ысулын кулланды: бөтен ачуын берьюлы елмаюы белән эретте дә ташлады:

— Я, я, булды! — диде.— Сез бик батыр егетләр: көндез — горур, төнлә — турылыклы. Башкаларны бик әйбәт саклагач, үз-үзеңне саклау бер дә гаеп түгел. Әфәнделәр, теге төнне «Күгәрчен оясы»на барганда мине саклаганыгызны бер дә онытмадым әле. Әгәр менә хәзер мин бара торган юлда берәр куркыныч булса, мин сездән үземне озатып куюыгызны үтенер идем, гәрчә андый куркыныч күренми, шулай булгач, монда гына калыгыз инде, шешәләрегезне эчеп, уеныгызны уйнап, хатыгызны укып бетерегез. Сау булыгыз, әфәнделәр.

Каюзак китергән атына атланып алгач, кардинал кулын селкеп саубуллашты да чаптырып китеп барды.

Дүрт егет, бер сүз эндәшмичә, тораташ кебек катып, кардинал күздән югалганчы карап тордылар.

Аннары гына бер-берсенә карашып алдылар.

Бөтенесенең дә чырайлары борчулы-аптырашлы иде: кардинал дусларча саубуллашкан кебек булса да, аның яман бер ачу белән киткәнлеге бик яхшы аңлашыла иде аларга.

Бер Атос кына исе китмәгән, батыр төс белән елмая иде. Кардинал инде боларны күрмәслек тә, ишетмәслек тә булып ерагайгач, ачуын кая куярга белмәгән Портос:

— Шушы аңгыра баш Гримо алданрак абайламаган бит! — дип куйды.

Гримо үзен аклап нидер әйтмәкче иде дә, Атос бармагын күтәргәч, хезмәтче дәшми калды.

— Хатны биргән булыр идегезме, Арамис? — дип сорады д'Артаньян.

— Мин мондый карарга килгән идем: әгәр ул хатны сораса, бер кулым белән хатны бирә йдем, кылыч тоткан икенче кулым белән кардиналны аркылы тишә идем,— дип матур, нәфис тавышы белән җавап кайтарды Арамис.

— Мин дә нәкъ шулай уйлаган идем,— диде Атос.— Шуңа күрә сезнең арага сүзгә катнаштым. Дөрес, ул кеше ирләр белән алай сөйләшкәндә бик саксыз эш итә. Моңарчы ул гел хатын-кыз һәм бала-чага белән генә сөйләшкән дип уйларсың.

— Атос дус, мин сезнең тотышыгызга соклансам да, ахыр

чиктә без барыбер хаклы түгел бит,— диде д'Артаньян аның бу сүзенә каршы.

— Ничек инде хаклы түгел! — диде Атос ачуы килеп.— Без сулый торган һава кемнеке ул? Безнең күз алдыбызда җәелеп яткан океан кемнеке? Без кызынып яткан ком кемнеке? Ә сөяркәгез язган хат кемнеке? Кардиналныкымыни? Ант әгәр, ул кеше бөтен дөньяга мин хуҗа дип уйлый. Сез аның каршында аптырап, мескен булып, сүзегезне җүнләп әйтә алмыйча басып тордыгыз... Сезнең инде күзегезгә Бастилия күренәдер, бик дәү Медуза сезне ташка әйләндерә сыман тоеладыр кебек иде. Әйтегез әле, гашыйк булу заговор кору дигән сүзмени ул? Сез кардинал тотып төрмәгә япкан бер хатынны яратасыз, аны кардинал кулыннан коткарырга телисез. Сез кардинал хәзрәтләре белән яшерен көрәш алып барасыз, бу хат — сезнең кузырыгыз. Карталарыгызны дошманыгызга күрсәтү нигә кирәк? Алай эшләмиләр. Кирәк булса, рәхим итеп, үзе белсен! Без аның хәйләләрен үзебез чишәбез бит!

— Чыннан да, Атос, сезнең әйткәннәрегез бик дөрес,— диде д'Артаньян килешеп.

— Алайса әлеге хәл турында бүтән бер сүз дә сөйләшмик. Арамис, кардинал бүлдергән җирдән башлап, тудыкасының хатын укып китсен.

Арамис хатны кесәсеннән чыгарды, өч дусты аңа якынрак елыштылар, хезмәтчеләр исә яңадан теге дәү шешә тирәсенә җыелдылар.

— Сез бит бер-ике генә юлын укып өлгергән идегез, шулай булгач, өр-яңадан башлагыз инде,— диде д'Артаньян.

— Яхшы,— диде Арамис.

— «Кадерле тудыкам, мин Стенәгә китәрмен, ахры, апам безнең асрау кызыйны шундагы кармелиткалар монастырена урнаштырган иде. Бичара кыз инде үзенең язмышына буйсынган, башка җирдә яшәсә, үзенең җанын харап итүе ихтималын белә ул. Әмма безнең гаилә хәлләребез үзебез теләгәнчә җайланса, ул, үзенең җанын харап итүдән дә курыкмыйча, тәвәккәлләп, сагынган кешеләре янына кайтып китәр шикелле, чөнки үзе турында гел уйлаганлыкларын белә ул. Ә хәзергә ул алай бик үк бәхетсез түгел: аның бердәнбер теләге — сөйгән егетеннән хат алу. Мин андый товарның монастырь рәшәткәсе аша җиңел генә узмаганлыгын беләм, шулай да, кадерле тудыкам, минем инде сезгә исбат итеп караганым бар — мин алай бик үк булдыксыз кеше түгелмен, ул йомышны башкарып чыгармын дип беләм. Апам сезгә үзен гел искә алып торуыгыз өчен рәхмәтен белдерә. Бер ара ул бик борчылган иде, хәзер инде беркадәр тынычланды: тегендә көтелмәгән бер-бер хәл булып куймасын дип, ышанычлы кешесен җибәрде.

Сау булып торыгыз, кадерле тудыкам, үзегез турында ешрак языгыз, ягъни безгә хат-хәбәрегезне җибәрергә ышанычлы җай чыккан саен яза торыгыз. Сезне үбеп,

*Мари Мишон».*

— Һай, минем өчен нинди зур эш эшләдегез сез, Арамис! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды д'Артаньян.— Кадерле Констанция! Аның хәбәрен дә ишетер көнем булыр икән ләбаса! Ул исән, ул монастырь эчендә, куркынычсыз җирдә, ул Стенэдә! Атос, ничек уйлыйсыз, кай тирәдәрәк булыр ул?

— Лотарингиядә, Эльзас чигеннән берничә генә лье. Камаудан туктау белән, без ул якларга барып кайта алабыз.

— Озак та көтәргә туры килмәс дип ышаныйк,— дип Портос та сүзгә кушылды,— бүген иртән бер шымчыны астылар. Шул шымчы әйтте: Ларошель кешеләре итек күне ашый башладылар, диде. Күннәрен ашап бетергәч, олтаннарына керешерләр дип уйласак, аннан ары, белмим, нәрсә ашарлар — шул, берберсен тотып ашасалар гына инде.

— Бичара сабыйлар! — дип куйды Атос, бик шәп Бордо шәрабын эчә-эчә; ул заманда бу шәраб хәзерге шикелле үк мактаулы булмаса да, сыйфаты хәзергедән бер дә ким булмаган.— Бичара сабыйлар! Әйтерсең католик дине бөтен диннәр арасында иң җайлысы, иң күңеллесе түгел!.. Шулай да чын егет алар...— диде, шәрабны эчеп бетереп, телен шартлатып куйды.— Ай, шайтан алгыры, нишлисез сез, Арамис? Хатны кисәгезгә яшерәсез түгелме? — диде аннары.

— Әйе шул, Атос дөрес әйтә, хатны яндырырга кирәк,— диде д'Артаньян, аның сүзен куәтләп.— Яндырсаң да әле, кем белгән, бәлки, кардинал көлне дә сөйләтү серен беләдер?

— Беләдер, беләдер,— диде Атос.

— Ул хатны нишләтмәкче буласыз соң? — дип сорады Портос.

— Гримо, килегез әле монда,— диде Атос.

Гримо, торып, хуҗа әфәндесе янына килде.

— Рөхсәтсез сөйләшкәнегезнең җәзасы итеп шушы кәгазь кисәген кабып йотарсыз, дустым. Аннары безгә эшләгән яхшылыгыгыз өчен шушы стакан белән шәраб эчәрсез. Менә сезгә иң элек хат, әйбәтләп чәйнәгез аны.

Гримо елмаеп куйды да, Атос мөлдерәмә итеп тутырган стаканга күзен төбәгән килеш, кәгазьне чәйнәп йотып җибәрде.

— Браво, булдырдың, Гримо! — диде Атос аны мактап.— Хәзер инде мәгез, стаканны тотыгыз. Ярый, рәхмәт әйтмәсәгез дә була.

Гримо, ләм-мим дәшмичә, бер стакан Бордо шәрабын йотып җибәрде, гарешкә төбәлгән күзләре бу эшнең үзенә ифрат ошаганлыгын сүзсез дә бик яхшы әйтеп тора иде.

— Кардиналның башына Гримоның корсагын ярып карау уе килмәсә, хәзер инде без беркадәр тынычлап яши алабыз дип уйлыйм,— диде Атос.

Бу вакытта кардинал хәзрәтләре әле һаман җайга гына сәйран кылып йөри, ә үзе авыз эченнән генә:

— Бу дүрт дусны, һичшиксез, мина хезмәткә күчерергә кирәк,— дип сөйләнә иде.

## XXII

## ТОТКЫНЛЫКНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨНЕ

Без, Франция ярларына күз ташлап, беравыкка миледины онытып торган идек; хәзер инде аңа әйләнеп кайтыйк.

Без аны шул өметсезлеккә төшкән, шомлы уйлар чоңгылына, дөм-караңгы җәһәннәм базына чумган хәлендә күрербез,— шушы җәһәннәмнең капкасы төбендә ул бөтен өмет-ышанычын диярлек югалтты: гомерендә беренче тапкыр ул шөбһәләнә-шомлана, гомерендә беренче тапкыр курка — коты чыга.

Бәхет инде аны ике тапкыр алдады, ике тапкыр аның мәкер хәйләсенә төшенеп, аңа яманлык эшләделәр, һәм уңышсызлыкка дучар булуының ике тапкырында да аны җиңеп чыгу өчен күктән иңгән явыз бер рух булды: моңарчы беркем каршында да җиңелеп калмаган явыз көч миледины д'Артаньян җиңде.

Д'Артаньян аның мәхәббәтен мыскыл итте, аның кешелек горурлыгын кимсетте, үз дәрәҗәсен күтәрүгә булган өметләрен алдады һәм менә хәзер инде ул аның бәхетен җимерә, аны иректән мәхрүм итмәкче була, хәтта аның дөньяда яшәвенә дә куркыныч тудыра. Алай гына да түгел: ул аның битлегенең бер читен, миледи гадәттә капланып йөри, үзен бик көчле итә торган калканның бер кырыен ача төште.

Д'Артаньян Бекингэмны королева белән бәйләнешле җилдавылдан коткарып калды, ә миледи, элек яратканнарының барысына да нәфрәт тоткан кебек, Бекингэмны да дошман күрә. Аның йөрәгендә бер ара де Вардка карата, гомумән, аның табигатендәге хатын-кызлар дәрте шикелле, тыелгысыз бер ана юлбарыс дәрте кабынды. Һәм шунда д'Артаньян де Вард кыяфәтендә килеп алдады аны. Д'Артаньян аның бик яман серен дә белә, ә миледи, минем ул серемне белгән кеше дөньяда яшәмәячәк, дип ант иткән иде. Һәм, ниһаять, дошманыннан үч алырга ярдәм итәргә тиешле рөхсәт кәгазен кулына төшерү белән шул кәгазьне милединың кулыннан тартып алдылар. Тагын шул ук д'Артаньян аны тоткынлыкка төшерде һәм аны Һинд океанындагы берәр җирәнгеч Ботанибейга яисә җан өшеткеч Тайбернга олактырачак.

Һичшиксез, аның бөтен бәхетсезлекләре шул д'Артаньян аркасында булды бит: аны шулкадәр хурлыкка төшергән кеше ул булмыйча кем булсын тагын? Милединың күрәчәгенә каршы, фәкать д'Артаньян гына аның әлеге куркыныч серләрен бер-бер артлы ача килеп, шуларны лорд Винтерга хәбәр иткән. Ул милединың кайнагасын яхшы белә һәм, тәгаен, д'Артаньян хат язган аңа.

Никадәр ачу-нәфрәт кайный милединың эчендә!

Ул, утлы күмер төсле көйрәгән күз карашын буш бүлмәнең түр ягына төбәп, бер хәрәкәтсез утыра; ара-тирә сулышы белән бергә күкрәгеннән аһылдаган бер аваз да чыгып куя һәм бу аваз шушы шыксыз, тәкәббер замок астындагы кыя ташларына,

һан иде. Миледи менә бу бүлмәдә инде бер сәгатьтән артык утыра, шуңа күрә озакламый аңа ашарга китерергә тиешләрдер. Әсир хатын, вакытны бушка әрәм итәргә теләмичә, шушы кичне үк җирлек капшап карарга, үзен сакларга тиешле кешеләрнең характер-холыкларын белешә башларга булды.

Менә ишек астыннан ут яктысы күренде; бу якты төрмәчеләрнең берегә килүен белгертә иде. Миледи тора башлаган җиреннән тиз генә янадан креслога утырды; башын ул артка ташлаган, матур чәчләрен иң өсләренә таратып салган, бөгәрләнгән челтәрләре каплап торган күкрәге бераз ачыла төшкән, бер кулын йөрәге турысына куйган, икенчесе креслодан салынып төшкән иде.

Ишек бикләре шалтыр-шолтыр килүгә, шыгырдап ишек ачылды, бүлмә эчендә аяк тавышлары ишетелде.

— Бу өстәлне анда кертеп куегыз,— диде кемдер; миледи моның Фельтон тавышы икәнлеген таныды.

Кушканны эшләделәр.

— Шәмнәр китерегез һәм сакчыны алмаштырыгыз,— диде Фельтон.

Лейтенант егетнең бер үк кешеләргә ике тапкыр боеруыннан миледи аңа шул ук үзен саклаучы кешеләр, ягъни солдатлар хезмәт күрсәтә икәнлегенә ышанды.

Өстәвенә Фельтонның боерыкларын берсүзсез йөгерә-йөгерә үтиләр, монысы инде аның үз кул астындагыларны каты тәртиптә тотуын әйтеп тора иде.

Миледига әле бер тапкыр да күз салмаган Фельтон, ниһаять, аңа таба борылды.

— Ә-ә! Йоклый икән. Яхшы, уянгач ашар,— диде дә ишеккә таба атлый башлады.

— Юк ла, лейтенант әфәнде, бу хатын йокламый,— дип, миледи янына килгән солдат Фельтонны туктатты; башлыгы шикелле кырыс түгел иде ул.

— Ничек — йокламый? Нишли соң ул? — дип сорады Фельтон.

— Һуштан язган ул. Йөзе ап-ак, тыңлап-тыңлап карадым — сулу алганы да ишетелми.

Фельтон миледига бер адым да якынаймастан, баскан урыныннан гына күз салып:

— Дөрес әйтәсез, лорд Винтерга тоткынның һуштан язганлыгын хәбәр итегез; көтелмәгән хәл бу, мин нишләргә икәнен белмим,— диде.

Офицерның кушканын үтәргә дип, солдат чыгып китте. Фельтон ишек төбендәге креслога утырды да, бер сүз сөйләшмичә, селкенмичә, көтеп тора башлады. Хатын-кызларның оста бер хәйләсен: күзне йомган шикелле, озын керфекләре арасыннан гына карап торуны миледи да бик яхшы белә иде; ул үзенә таба арты белән утырган Фельтонны күрде; күзен алмыйча бер ун минут чамасы карап торды, һәм шул вакыт эчендә аның кырыс сакчысы бер тапкыр да борылып карамады.

мәңгелек аһ-зар шикелле, бәрелеп-җимерелеп торган дулкыннар шавына кушылып китә!

Милединың кайнар ярсу-нәфрәт уты белән янган күңеле киләчәктә Бонасье ханымнан, Бекингэмнан, бигрәк тә д'Артаньяннан бик каты, бик яман итеп үч алу планнары кора!

Анысы шулай, әмма үч алыр өчен иректә булу кирәк бит, иректә булыр өчен исә, төрмә шикелле җирдә тоткын булып ятканда, стенаны тишәргә, рәшәткәне кисәргә, идәнне актарырга кирәк; ә андый эшне көчле-таза, түземле ир кеше генә башкарып чыга ала, хатын-кыз аны булдыра алмый, ачу-гарьлектән ярсыган хәлендә бигрәк тә шулай. Өстәвенә моның өчен вакыт кирәк, айлар, еллар кирәк, ә аның... аның туган җанлы, усал төрмәче лорд Винтер әйткәнчә, алда нибары ун-унике көн вакыты бар.

Әгәр ул ир кеше булса, мондый эшкә керешеп карар һәм, ихтимал, уңышка да ирешер иде. Шушындый йомшак, нәфис гәүдәгә ходай ирләр рухы биреп нигә хаталык кылды икән!

Шуңа күрә тоткынлыкның беренче минутлары аңа коточкыч газаплы тоелды: миледи ачу-ярсуыннан тетрәнүен-калтырануын баса алмады, хатын-кызга хас йомшаклык табигый тойгыларга ирек куйды.

Әмма тыелмаслык булып кайнаган ачу-ярсуын ул әкренләп баса башлады, бөтен тәнен тетрәткән нерв өянәге туктады, арган елан хәл алган кебек, миледи утырган җирендә йомарлана төште дә хәл җыя башлады.

— Я, җитте инде, булды! Бу кадәр ярсынып акылымнан шашканмын,— диде ул көзгегә күз салып; көзгедә чагылган утлы күмер төсле карашы гүяки аның үзеннән җавап сорый иде.— Дуамалланырга ярамый, дуамаллык ул — көчсезлек билгесе. Өстәвенә, андый чара белән беркайчан да уңышка ирешә алганым юк. Хатын-кызлар белән эш итеп, көч куллансам, бәхеткә каршы, бәлки, җиңеп тә куяр идем. Әмма мин бит ирләр белән көрәшәм, ә алар өчен мин көчсез бер хатын-кыз гына. Ярар алайса, хатын-кыз коралы белән көрәшербез: минем көчем дә — көчсез булуымда.

Теречән, чибәр йөзенә нинди үзгәрешләр кертә алырын үз күзе белән күреп ышанырга теләгәндәй, ул бөтен чыраен бозган ачу-ярсудан башлап, иң юаш, иң мөлаем һәм иң сөйкемле елмаюга хәтле, йөзенә алмаш-тилмәш барлык төс-кыяфәтне чыгарып карады. Аннары, йөзенең чибәрлеген тагы да арттыру өчен, оста куллары чәченең рәвешен үзгәртергә кереште. Ахырында, үз-үзеннән бик канәгать булып:

— Өмет бөтенләй үк бетмәгән әле. Һаман да чибәр әле мин,— дип пышылдады.

Кичке сәгать сигезләр тирәсе иде. Милединың бүлмә эчендәге караватка күзе төште: бераз ял итеп алсам, башым белән акылым гына түгел, йөзем дә сафланып, ачылып китәр, дип уйлады. Ләкин, йокларга ятканчы, башына тагы да яхшырак бер уй килде. Ул кичке аш хакында сөйләшүләрен ишетеп кал-

Миледи менә хәзер лорд Винтер килеп житәчәген исенә төшерде, аның килүе төрмәчегә яңа көч бирәчәген уйлады. Милединың беренче тәҗрибәсе барып чыкмады, запаста андый чаралары байтак булган хатын-кыз кебек, бу уңышсызлыгына ул борчылмады, башын күтәреп, күзен ачты да җиңелчә генә көрсенеп куйды.

Бу тавышны ишеткәч, Фельтон ниһаять борылып карады.

— Ә, менә сез дә уяндыгыз, ханым! — диде ул.— Димәк, минем монда эшем бетте! Әгәр сезгә берәр нәрсә кирәк булса, чылтыратырсыз.

Миледи, борынгы сихерче хатыннар шикелле, харап итәргә теләгән кешесен таң калдыра торган матур бер тавыш белән:

— Ай аллам! Ай аллам! Хәлем бик начар шул! — дип пышылдап кына сөйләнеп куйды.

Һәм креслосында турая төшеп, моңарчы яткандагыдан сөйкемлерәк, иркенрәк бер рәвешкә керде.

Фельтон урыныннан торды.

— Ханым, сезгә көненә өч тапкыр ашарга китерерләр, иртән сәгать тугызда, көндез бердә, кич сигездә. Әгәр мондый тәртип ошамаса, мин әйткәннәр урынына үз вакытыгызны әйтә аласыз, шуннан без сезнең теләкне искә алып эш итәрбез,— диде.

— Шушы зур, шыксыз бүлмәдә мин һаман бер ялгызым яшәрменме? — дип сорады миледи.

— Күршедә яши торган бер хатынны чакырдылар. Иртәгә ул замокка килә, аннары сез кайчан телисез, шул чагында яныгызга керер.

— Рәхмәт,— диде тоткын хатын юаш кына.

Фельтон иелебрәк баш иде дә ишеккә таба китте. Ул бусагадан атлап чыгам дигәндә генә коридорда милединың һуштан язганлыгын әйтергә дип киткән солдат белән лорд Винтер күренде. Лорд кулына кечкенә шешә белән борынга иснәтә торган тоз тоткан иде.

Әсир хатынның торып аягына басканлыгын, ә Фельтонның китәргә җыенуын күреп, лорд Винтер көлгән сыман бер тавыш белән:

— Я, ни булды? Ни тамаша бар монда? — дип сорады.— Димәк, үлгән дигәнегез яңадан терелгән? Фельтон, балам, үзеңне яңа кеше дип, синең алда комедиянең беренче пәрдәсен уйнаганлыкларын төшенмәдеңмени, шайтан алгыры? Ул комедияне без, һичшиксез, ахырына чаклы карарбыз әле!

— Мин дә нәкъ шулайдыр дип уйладым, милорд,— дип җавап бирде Фельтон.— Тоткыныбыз хатын-кыз булгач, мин инде аңа беркадәр илтифат күрсәтергә теләгән идем,— яхшы тәрбияле һәр кеше, хатын-кыз хакына булмаса, һич югы, үзенең кешелек дәрәҗәсе өчен, аңа илтифат күрсәтергә тиеш бит.

Милединың бөтен тәне калтырана башлады. Фельтонның бу сүзләре әсир хатынның бәгыренә салкын боз булып төште.

— Алайса бик оста итеп таратып салган бу матур чәчләр, бу ап-ак тән һәм моңсу күз карашы син таш йөрәкне эретеп өлгермәде әле? — дип көлеп сорады лорд Винтер.

— Юк, милорд,— дип җавап бирде таш йөрәкле егет,— ихластыр, мине эретер өчен хатын-кызның хәйләсе белән мутлыгы гына җитми шул.

— Алайса шул, батыр лейтенантым, миледи үзенең башка чарасын эзли торсын, ә без ашарга китик. Һи, бер дә борчылма, аның башы бик яхшы эшли, озакламас, комедиянең икенче пәрдәсе дә булыр.

Шулай дип, лорд Винтер Фельтонны култыклады да, көлә-көлә, аны алып чыга башлады.

— О, синең өчен кирәк чарасын табармын мин,— дип, тешен кысып пышылдады миледи,— бер дә борчылма, ялгыш юлга киткән бичара монах, пешеп җитмәгән солдат аламасы, сиңа мундир түгел, монах җиләне киясе калган!

— Һи, миледи,— диде Винтер, бусагада туктап,— бу уңышсызлыгыгызга карап аппетитыгызны бозмагыз инде. Чеби итеннән, балыгыннан авыз итегез, ант әгәр, мин аларга агу салырга кушмадым. Мин үземнең пешекчемнән бик канәгатьмен, мин үлү белән миннән мирас өмет итмәгәч, мин аңа тулысынча ышанам. Миннән үрнәк алыгыз. Сау булып торыгыз, сөекле сеңлем! Янә һушыгыздан язганга хәтле!

Бу кадәресенә инде миледи түзә алмады: куллары белән, тетрәнә-тетрәнә, креслога ябышты, чытырдатып тешләрен кысты һәм лорд Винтер белән Фельтон артыннан ишекнең ябылганын карап торды; ялгызы калгач, тагын өметсезлеккә бирелде. Өстәл өстенә күзе төшеп, шунда ялтырап яткан пычакны күрде дә, тиз генә ташланып, аны кулына алды: пычак бөгелә торган көмештән ясалган, очы түгәрәкләнебрәк тора иде.

Ябылып бетмәгән ишек артында шаркылдап көлеп җибәрүләре ишетелде дә ишек яңадан ачылды.

— Ха-ха! Ха-ха-ха! — диде лорд Винтер.— Күрдеңме инде, Фельтон дус, күрдеңме, мин сиңа нәрсә дидем: ул пычак синең өчен дип хәзерләп куелган булган, шуның белән ул сине кадап үтергән булыр иде. Беләсеңме, аның бер кимчелеге бар: үзенә комачаулый торган кешеләрдән ничек итеп булса да котылырга тырыша ул. Әгәр мин синең сүзне тыңлап, аңа үткен очлы корыч пычак бирдергән булсам, Фельтонның эше беткән дә булыр иде; башта ул сине чәнчеп үтерер иде, аннары — безне! Күрәсеңме, Джон, нинди оста тота ул пычакны!

Чыннан да, миледи әле һаман да пычакны кулында чытырдатып кысып тотып тора иде, тик әлеге бик яман мыскыл сүзләре аның кул җегәрен, көчен һәм ихтыярын алган кебек булды.

Пычак чалтырап идәнгә төшеп китте.

Фельтон милединың бәгыренә кадалырлык тирән бер нәфрәт тоны белән:

— Сүзегез хак, милорд, мин ялгышканмын,— диде.

Алар тагын чыгып киттеләр.

Бу юлы инде миледи ишек ягына ныграк колак салды, алар китеп, коридорның аргы башында аяк тавышлары тынганны көтеп торды.

— Беттем, — дип пышылдады. — Минем хәйләләрем, бронза яки гранит сынга тәэсир итмәгән кебек, бу кешеләргә дә үтә алмый. Мин әнә шундый кешеләр кулында хәзер. Алар мине үтәли беләләр, минем бернинди коралыма да бирешмиләр. Әмма алар уйлаганча булуына һич тә юл куярга ярамый.

Чыннан да, милединың соңгы фикеренә караганда, аның инстинктив рәвештә өмете янаруы бу көчле рухны курку хисе дә, көчсезлек тойгысы да озак басып тора алмаганлыгын күрсәтә иде. Ул өстәл янына утырып, төрле ризыктан авыз итеп карады, бераз испан шәрабы эчте һәм шуннан соң үзенә көч-рух кайтканлыгын тойды.

Йокларга ятканчы, әлерәк үзе белән сөйләшкән кешеләрнең сүзләрен, гамәлләрен, кул хәрәкәтләрен, аз гына селкенүләрен һәм хәтта сүзсез торуларын да бөтен яктан тикшереп, уйлап, бәяләп чыкты һәм, шушы җентекле, оста тикшерүнең нәтиҗәсе буларак, ике залимнан Фельтон исемлесе йомшаграк дигән ышанычы туды. Бигрәк тә лорд Винтерның бер сүзе әсир хатынның әледән-әле исенә төшкәләп торды:

— Әгәр дә мин синең сүзеңне тыңлаган булсам,— диде ул Фельтонга.

Лорд Винтер аның сүзен тыңламаган икән, димәк, Фельтон миледи файдасына сөйләгән булган.

— Димәк, бу кешенең күңелендә ни дәрәҗәдәдер мине кызгану чаткысы бар,— дип уйланды миледи.— Мин ул чаткыдан аның эчендә ялкын дөрләтермен. Ә лорд Винтер мине белә инде, миннән курка ул, берәр вакыт аның кулыннан ычкынсам, миннән нәрсә көтәчәген бик яхшы аңлый ул, шулай булгач, аны буйсындырырга маташуның мәгънәсе юк. Менә Фельтон, ичмасам, бөтенләй башка кеше, саф күңелле, беркатлы егет, мәрхәмәтле дә бугай әле, аның менә башын-күзен әйләндерергә була.

Шуннан соң миледи ятты да елмайган килеш йоклап китте; менә хәзер берәр кеше аның йоклаганын карап торса, бу яшь кыз булачак бәйрәмдә киясе такыясы белән төшләнеп ятадыр дип уйлар иде.

## XXIII

## ТОТКЫНЛЫКНЫҢ ИКЕНЧЕ КӨНЕ

Миледи төшендә д'Артаньянны кулына төшергән итеп күрде, ул егетне җәзалап үтерүләрен тамаша кылып карап тора, имеш; явыз дошманы д'Артаньянның палач балтасы астыннан чәчрәгән канын күреп, төшендә әнә шулай искиткеч матур, сөйкемле итеп елмаеп ята иде ул.

Миледи беренче тапкыр өмет чаткысы күреп сөенгән тоткын шикелле йоклады.

Иртәгесен аның бүлмәсенә кеше кергәндә, ул караватында йоклап ята иде әле. Фельтон коридорда торып калган: ул кичә әйткән теге хатынны алып килгән иде; шул хатын бүлмәгә керде дә, миледи янына килеп, аңа булышырга әзер икәнлеген әйтте.

Милединың гадәттә чырае ак, һәм бу хатынны беренче тапкыр күргән кеше, аның йөз төсенә карап, алдануы да мөмкин иде.

— Минем бөтен тәнемне бизгәк тота, төн буе керфек тә какмадым, хәлем бик авыр... Кичә монда минем белән бик кешелексез кыландылар, сез миңа кешечәрәк карарсыз микән? Хәер, минем бөтен үтенечем шул — миңа ятып торырга гына мөмкинлек бирсеннәр иде,— дип сөйләнде ул.

— Сезгә, бәлки, врач китертергә кирәктер? — дип сорады хатын.

Фельтон, бер сүз эндәшмичә, бу сөйләшүне тынлап торды.

Миледи үз тирәсендә кеше күбрәк булса, үзен кызганучылар да күбәер һәм аннары лорд Винтер күзәтүне дә көчәйтә төшәр, дип уйлады; өстәвенә, врач килеп караса, аны авыруга салышып кына ята, дип әйтүе дә ихтимал, ә милединың беренче тапкыр хәйләсе барып чыкмаганнан соң, икенчесендә дә уңышсызлыкка очрыйсы килми иде.

— Доктор китертү нигә кирәк? — диде ул.— Бу әфәнделәр кичә минем авыруымны комедия дип кенә әйттеләр, бүген дә, һичшиксез, шулай диярләр: кичә кичтән бирле алар докторга искәртеп куярга өлгергәннәрдер инде.

— Ул чагында әйтегез, ханым: үзегез ничек дәваланырга телисез соң? — дип, Фельтон, түземе бетеп, сүзгә кушылды.

— Ай аллам, ничек дәваланасымны каян белим мин! Мин үземнең авыру икәнемне генә беләм, менә шул, теләсә нәрсә бирсеннәр,— миңа барыбер.

— Барыгыз, лорд Винтерны чакырып китерегез әле,— диде Фельтон, бу бетмәс зарлардан туеп.

— Юк! Юк! — дип кычкырды миледи.— Юк, зинһар, чакырмагыз, минем хәлем бик әйбәт, миңа берни кирәкми, тик чакыра гына күрмәгез!

Бу сүзләрен миледи шундый кайнарланып, шундый ышандыргыч итеп әйтте,— Фельтон ирексездән бусага аша узып бүлмә эченә керде.

«Килде ул»,— дип уйлап куйды миледи.

— Шулай да, ханым, әгәр сез чынлап та авырыйсыз икән, ул чагында врач чакыртабыз, әгәр алдашасыз икән, ул чагында инде үзегез өчен начар гына булыр, һәрхәлдә, без үзебезне гаепле санамабыз,— диде Фельтон.

Миледи җавап кайтармады, матур башын мендәргә төртеп, күз яше белән еларга кереште.

Фельтон гадәтенчә салкын бер сабырлык белән аңа беравык

карап торды; аннары милединың бу өянәге озакка сузылу ихтималын күреп чыгып китте; аның артыннан теге хатын да чыкты. Лорд Винтер күренмәде.

Миледи тыелгысыз бер сөенеч белән:

— Төшенә башладым бугай,— диде дә, үзенең шатлануын берәрсе карап-күреп тормасын дип, одеял астына кереп ятты.

Ике сәгатьләп вакыт үтте.

«Хәзер инде авыруыма бетәргә вакыт,— дип уйлады миледи.— Торыйк, бүген үк берәр уңышка ирешергә тырышып карыйк. Минем нибары ун гына көнем калды, бүген кич шул ун көннең икенчесе бетә бит инде».

Иртән миледига аш китерә керделәр; озакламый, ашаганнан соң, өстәлне дә җыештырырлар, шунда Фельтонны тагын күрермен, дип уйлады миледи.

Һәм ялгышмады: Фельтон тагын бүлмәгә килеп керде, ләкин милединың ашка кагылганмы-юкмы икәнлегенә тамчы да игътибар итмәде, аш кертә торган өстәлне бүлмәдән алып чыгарга кушты.

Бөтенесен чыгарып җибәргәч, Фельтон үзе бүлмәдә калды; кулына бер китап тоткан иде ул.

Миледи исә камин янындагы креслога ята төшебрәк утырган, үзе чибәр-сөйкемле, ак чырайлы, буйсынган-юаш бер кыяфәтле — газаплы әҗәлен көткән изге кыз сыман иде.

Фельтон аның янына килде.

— Ханым, сезнең үз чиркәвегезнең йолаларын үтәргә, аның гыйбадәтләренә йөрергә мөмкинлегегез булмагач, сезнең өчен авыр булыр дип уйлый лорд Винтер,— ул да сезнең кебек католик бит,— шуңа күрә ул сезнең көн саен үз гыйбадәтегезнең догаларын укуыгызга ризалыгын белдерде. Ул догаларны сез шушы китаптан табарсыз.

Фельтонның миледи янындагы өстәлгә китапны нинди кыяфәт белән куюын, «үз гыйбадәтегезнең» дигән сүзне нинди тон белән әйтүен һәм кимсеткән шикелле елмаюын күреп, миледи башын күтәрде дә офицерга текәлебрәк карап алды.

Һәм шунда Фельтонның бик ыспай-тыйнак итеп таралган чәчен, артык гади киемен, мәрмәр кебек шома, салкын һәм жансыз маңгаен искәреп, аның корыга каткан бер пуритан икәнлеген төшенде. Мондый пуританнарны король Яков сараенда да, Варфоломей төнен онытмасалар да, вакыт-вакыт үзләренә сыеныр урын иткән француз короле сараенда да очратканы бар иде аның.

Бөтен язмышын, яшәешен хәл иткән кыен бер минутта даһи кешеләрдә генә була торган илһам ялкыны кинәт милединың күңелен яктыртып җибәрде.

«Үз гыйбадәтегезнең» дигән ике сүздән һәм Фельтонга тиз генә текәлеп карап алуыннан соң, миледи әйтәсе җавабының бик мәгънәле булырга тиешлеген төшенде.

Зиһене бик тиз эшләп, бу җавабын шундук уйлап та тапты.

Офицер егетнең тавышыннан сизелгән төслерәк кимсетүле бер тон белән миледи:

— Мин! Мин, әфәндем...— дип куйды,— минем гыйбадәтем догалары! Католик азгыны лорд Винтер минем аның белән бер дин тотмаганлыгымны бик яхшы белә бит, мондый тозак куеп, мине шуңа эләктерергә маташа ул.

— Сез нинди дин тотасыз соң, ханым? — дип гаҗәпсенеп сорады Фельтон, үз-үзен кулда тота белсә дә, бу юлы ул гаҗәпләнүен сиздерми кала алмады.

Миледи, әсәренгән-ярсынган булып, кычкыра төшеп җавап кайтарды:

— Динем өчен кайчан җитәрлек газап чигәрмен, менә шунда әйтермен!

Фельтонның күз карашыннан миледига үзенең тырышлыгында шушы бер сүзе белән күпме алга киткәнлеге аңлашылды.

Әмма офицер егет бер сүз эндәшмәде, бернинди хәрәкәт ясамады, фәкать аның күз карашы гына барысын да әйтеп тора иде.

— Мин дошманнарым кулына килеп эләктем,— диде миледи пуританнардан откан күтәренке бер тон белән.— Бер ходаема гына ышанып яшим мин! Ходай я коткара мине, я мин аның хакына һәлак булам! Минем җавабым менә шул. Аны лорд Винтерга тапшыруыгызны үтенәм. Ә бу китапны,— диде, догалыкка бармагы белән төртеп күрсәтте, шуңа орынып пычранудан курыккан кебек, китапка бармагын тидермәде,— бу китапны алып китегез дә үзегез файдаланыгыз, чөнки сез, һичшиксез, лорд Винтерның бер генә түгел, икеләтә ярдәмчесе, җәберзолымда һәм денсезлектә уртак тел табасыз.

Фельтон җавап бирмәде, баягыча җирәнеп кенә китапны алды да уйга калып чыгып китте.

Кичке сәгать бишләр тирәсендә лорд Винтер килде: милединың алда үзен ничегрәк тотарга тиешлеге турында уйланырга көн буена җитәрлек вакыты булды. Кайнагасын ул ярыйсы ук тынычланып җиткән бер хатын кебек кабул итте.

Барон миледи каршына креслога җәелеп утырды да аякларын камин каршындагы келәмгә сузгалап:

— Без беркадәр мөртәтлек кылдык бугай! — диде.

— Бу сүзегез белән ни дип әйтмәкче буласыз, галиҗәнап?

— Шуны әйтмәкче булам: соңгы тапкыр күрешүебездән бирле сез динегезне алмаштыргансыз икән. Әллә өченче иргә — протестантка чыктыгызмы?

— Аңлатыбрак сөйләгез, милорд,— диде әсир хатын мәһабәт бер тон белән,— мин сезнең сүзләрегезне ишетсәм дә, мәгънәсен төшенмим.

— Димәк, сез бөтенләй дин тотмыйсыз, монысы тагы да ошый төшә миңа,— диде лорд Винтер көлебрәк.

— Әлбәттә, ул сезнең кагыйдәләрегезгә бик җайлы килә,— диде миледи салкын гына.

— Ихластыр, минем өчен анысы барыбер.

— Дин мәсьәләләренә битараф булуыгызны әйтмәсәгез дә, җенси бозыклыгыгыз белән башбаштаклык кылуыгыз да сезне фаш итәр иде, милорд.

— Һе! Мессалина ханым, леди Макбет, җенси бозыклык турында сез сөйлисезме?! Я мин әйбәтләп ишетеп җиткермәдем, я инде, шайтан алгырысы, сез бик оятсыз хатын!

— Безне тегеннән тыңлап торуларын белгәнгә күрә, төрмәчеләрегез белән палачларыгызны миңа каршы котыртыр өчен шулай әйтәсез бит сез,— диде миледи салкын гына.

— Төрмәчеләрне! Палачларны! Менә бит, ханым, сез патетик тонга бирелеп китәсез, һәм кичәге комедия бүген инде трагедиягә әйләнеп бара. Хәер, бер атнадан инде сез тиешле җирегезгә барып җиткән булырсыз, минем ният җиренә җиткереп үтәлер.

— Хурлыклы ният! Намуссыз ният! — диде миледи, хөкем итүчесенә каршы нәфрәтләнгән гаепсез корбан экзальтациясе белән.

— Ант әгәр, бу бозык хатын акылыннан яза бугай! — дип, лорд Винтер урыныннан торды.— Ягез, җитте, тынычланыгыз инде, пуритан ханым, югыйсә төрмәгә яптырып куюым да бар үзегезне. Валлаһи, мин китерткән испан шәрабы сезнең башыгызга киткәндер! Хәер, бер дә борчылмагыз, алай исерү генә куркыныч түгел, әллә ни яманлыгы булмас.

Шулай дигәч, лорд Винтер, ул заманда хәтта югары җәмгыять кешеләренең дә гадәтендә булганча, сүгенә-сүгенә чыгып китте.

Фельтон чыннан да ишек артында боларның бөтен сүзен ишетеп торган иде.

Миледи, билгеле, моны сизми калмады.

— Бар, бар, олак! — дип пышылдап калды ул кайнагасы артыннан.— Яманлык дигәнең озакламый үзеңә килеп җитәр, тик син, ахмак, эш узгач кына сизәрсең шул аны.

Бүлмә эче тагын тынып калды. Тагын ике сәгатьләп вакыт узды. Солдатлар, кичке ашны китергәч, милединың кычкырып дога укып утыруын күрделәр,— ул догаларны аңа икенче иренең карт бер хезмәтчесе, бик тәкъва пуритан өйрәткән иде. Миледи әллә нинди бер экстазга бирелгән дә үз тирәсендә кешеләрнең ни эшләп йөрүләренә дә игътибар итми кебек иде. Фельтон аңа комачауламаска дип ишарә итте һәм, аш әзерләнеп беткәч, солдатлар белән бергә шыпырт кына чыгып китте.

Миледи ишектәге кечкенә тәрәзәдән үзен күзәтеп торулары ихтималын белә иде, шуңа күрә догаларын иң соңгысына хәтле укып чыкты һәм шунда аңа ишек төбендәге сакчының йөреше моңа чаклы булганына охшамаган, сакчы ишеккә килеп, тыңлап-тыңлап тора сыман тоелды.

Бу кичне инде миледига бернәрсә дә кирәк түгел иде, ул торып өстәл янына килеп утырды да бераз аш ашады, шәрабны капмады, су гына эчте.

Бер сәгатьтән соң солдатлар өстәлне алырга килделәр, миледи шунда Фельтонның бу юлы алар белән килмәгәнлеген искәрде.

Дкмәк, миледины еш күрергә курка иде ул.

Миледи йөзен стенага таба борып елмаеп куйды: сөенече шулхәтле көчле иде аның — үз-үзен фаш итүе дә ихтимал иде.

Ул тагын ярты сәгать чамасы көтте. Иске замок эче тирән тынлыкка чумган, бары тик мәңгелек диңгез шавы белән иксез-чиксез дәрьяның сулу алганы гына ишетелеп тора иде... Миледи яңгыравык, саф, матур тавыш белән пуританнарның яраткан псалмысыннан беренче аятьне җырларга керешүе:

И тәңре, безне ташлыйсың,
Безнең көчне сынамакта,
Янә шәфкатең саласың
Түзә белгәнгә газапта.

Шигырь, әлбәттә, шигъри камиллектән бик ерак иде, билгеле булганча, пуританнарның поэтик осталык ягы әллә ни мактанырлык түгел иде.

Миледи җырлый-җырлый ишек ягына колак салды: сакчы, аның ишек төбенә җиткәч, шып туктап калды. Бу хәлдән миледи сакчыга җырлавының нинди тәэсир ясаганлыгын төшенде.

Һәм шуннан соң ул чамадан тыш хисләнеп-дәртләнеп тагы җырларга тотынды; аның җыры замок гөмбәзе астында бик еракка таралып, тылсымлы бер аваз шикелле, төрмәчеләрнең күңелләрен нечкәртәдер кебек тоелды. Ләкин сакчы бик диндар бер католик иде булса кирәк,— бу тылсымнан тиз генә арынды да ишек аша:

— Җитәр, туктагыз, ханым, сезнең җырыгыз, мәет озаткандагы җыр шикелле, эчне пошыра, бередә гарнизонда торудан тыщ, тагын мондый җырлар да тыңлый башласаң, бөтенләй түзеп булмас аннары,— дип кычкырды.

Кемдер шунда бик усал итеп сакчыга:

— Тыныгыз! — дип боерды, һәм миледи моның тавышыннан Фельтон икәнлеген таныды.— Ник сез үзегезгә тиешле булмаган эшкә тыгыласыз, җүнсез? Бу хатынны җырлатмагыз дигән боерык бирелдеме сезгә? Юк. Сезгә аны сакларга, качарга маташса, атарга куштылар. Саклавыгызны белегез: качарга уйласа, атыгыз да үтерегез. Ләкин үзегезгә бирелгән боерыктан узып эш итмәгез.

Милединың йөзен, ялт итеп кабынып алган яшен яктысы шикелле, әйтеп бетергесез шатлык-сөенеч нуры яктыртып җибәрде, һәм ул, әлеге сөйләшүнең бер генә сүзен ычкындырмаса да, аны бөтенләй ишетмәгән дә кебек, шундук, тавышына иблис биргән бөтен яңгыравыгын, бөтен матурлыгын, тылсымлы аһәңен салып, яңадан җырларга тотынды:

Түзәр яшьлек аһ-зар, авыр көрәш,
Тоткынлыкка, богауларга,
Гыйбадәт бар — шашынулы —
Хәсрәт көннәрен санарга.

Милединың дәртле рух белән сугарылган гаҗәеп матур яңгыраулы тавышы псалмның дорфа, килешсез шигыренә күңелне әсәрләндерерлек тылсымлы бер көч бирә — хисчән пуританнар бу җырны бөтен дәрт-хыяллары белән бизәп үз туганнары җырлаган чакта да мондый тылсымлы көчне бик сирәк тойганнардыр. Фельтонга исә тәмуг утында дөрләп янган өч яһүд малаен юатучы фәрештә җырын ишетә кебек тоелды.

Миледи җырлый бирде:

Тик килер котылыр вакыт
Безнең өчен, бер ходаем!
Алдамаса безне ирек,
Һич алдамас әҗәл-үлем.

Гүзәл тылсымчы бөтен рухын-җанын салып җырларга тырышкан бу шигырь офицер егетнең йөрәк газабын соңгы чигенә җиткерде; ул кисәк кенә ишекне ачып җибәрде дә миледи каршына кереп басты,— гадәтенчә, аның йөзе агарынган, күзләре очкынланып ялт-йолт килә иде.

— Нигә сез шулай җырлыйсыз, шундый тавыш белән? — дип сорады ул.

— Гафу итегез,— диде миледи юаш кына,— мин бу йортта болай җырларга ярамаганлыгын онытып җибәргәнмен. Мин сезнең дини тойгыларыгызны рәнҗеткәнмендер, бәлки, әмма, ант итеп әйтәм, мин моны юри эшләмәдем. Гаебем өчен мине гафу итегез, гаебем зур булса да, ихластыр, ирексездән эшләнде.

Бу минутта миледи шул хәтле дә чибәр-сөйкемле иде, бөтен кыяфәтендәге дини бер экстаз аның йөзенә шундый илаһи төс биреп тора иде — ханымның гүзәллегеннән башы-күзе әйләнгән Фельтонга әле генә җыры ишетелгән фәрештә үзе егетнең каршысында басып тора кебек тоелды.

— Әйе, әйе. Әйе, сез замокта яшәүче кешеләрне борчыйсыз, күңелләрен тынычсызлыйсыз,— дип җавап бирде Фельтон.

Акылын җуйган бичара егет үзенең өзек-төтек сөйләшүен дә сизмәде, ул арада миледи исә үткен карашы белән аның күңел түренә үтеп керергә тырышты.

Тавышын бик юаш чыгарырга, буйсынган-карусыз бер кыяфәткә керергә тырышып аска карап кына:

— Бүтән җырламыйм инде,— дип куйды.

— Юк, юк, ханым, җырлагыз, тик әкренрәк кенә җырлагыз, бигрәк тә — төнлә,— диде Фельтон аның бу сүзенә каршы.

Шулай дигәч, ул, әсир хатынга артык озак кырыслык күрсәтә алмаячагын тоеп, бүлмәдән тиз генә чыгып китте.

— Бик яхшы эшләдегез сез, лейтенант әфәнде! Аның җыры җаннарны актарып ташлый. Хәер, бераздан күнегәсең аңа,— гаҗәеп бер тавыш аның тавышы! — диде солдат.

## XXIV

## ТОТКЫНЛЫКНЫҢ ӨЧЕНЧЕ КӨНЕ

Менә Фельтон тагын килде. Хәзер инде тагын бер адым ясап карыйсы бар: аны бүлмәдән чыгармый торырга, дөресрәге — аның белән икәүдән-икәү генә калырга кирәк иде. Тик миледи моны ничек эшләргә икәнен ачык итеп күз алдына китерә алмый иде әле. Икәүдән-икәү калу гына да җитми: Фельтонны сөйләштерергә кирәк, ул чагында миледи үзе дә аның белән сөйләшеп китә алачак,— ул инде үзенең иң зур тылсымы — кеше сөйләшеннән башлап фәрештә җырлавына хәтле төрле төсмерләргә кереп үзгәрә ала торган тавышында икәнлеген бик яхшы белә.

Шулай да, мондый ышанычына карамастан, милединың уңышсызлыкка очравы да ихтимал иде, чөнки Фельтон бик нык кисәтеп-искәртеп куелган иде. Шуңа күрә миледи аның бөтен хәрәкәт-кыланышын, һәр әйткән сүзен, иң гади карашын да, кул хәрәкәтен дә, хәтта көрсенгән кебек тоелырдай тын алуын да күзәтеп тора башлады. Кыскасы, ул, үз амплуасына туры килми торган яңа роль алган оста актер кебек, офицер егетнең бөтен ягын тикшерә-өйрәнә башлады.

Миледи өчен лорд Винтер янында үз-үзен тотышы мәсьәләсе әллә ни кыен түгел иде, өстәвенә ул алдагы көнне үк моны инде бик әйбәтләп уйлап куйган, кайнагасы барында сөйләшмәскә, үзен горур тотарга, ара-тирә юри исе китмәгән булып аның ачуына тияргә, берәр кимсеткеч сүз әйтеп, аны чыгырыннан чыгарырга һәм шуның белән үзенең юашлыгына аны капма-каршы итеп күрсәтергә карар кылган иде. Фельтон боларның һәммәсенә шаһит булачак, үзе бер сүз әйтмәсә дә, барысын күреп торачак.

Иртән Фельтон миледи бүлмәсенә гадәттәге вакытында килеп керде, ул иртәнге ашны әзерләтеп китерткән арада миледи аңа бер сүз дә эндәшмәде. Егет чыгып китәргә җыенган чакта гына милединың күңелендә өмет чаткысы чагылып алды: Фельтонның сөйләшәсе килгән кебек тоелды аңа; ләкин офицер егетнең иреннәре, бер аваз да чыгармыйча, кыймылдап кына куйды; ул, үзен көчләп, әйтә язган сүзләрен эченә йотты да чыгып китте.

Төш җитәрәк лорд Винтер килде.

Матур гына кышкы бер көн иде, Англиядәге яктыртса да җылытмый торган сүрән кояшның нурлары миледи төрмәсенең рәшәткәләре аша бүлмә эченә төшкән иде.

Миледи, тәрәзәгә караган килеш, ишек ачылганны ишетмәгәнгә салышты.

— Менә сиңа! — диде лорд Винтер көлеп.— Башта комедия уйнадык, аннары — трагедия, хәзер инде меланхолиягә бирелдек.

Әсир хатын җавап кайтармады.

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде лорд.— Сезнең бу як ярда

иреккә чыгасыгыз, ышанычлы корабка утырып, шушы диңгезнең зәбәрҗәт дулкыннарын ярып үтәсегез, миңа каршы,— судамы, коры җирдәме,— чая бер засада оештырасыгыз килә — андый эшкә сез бик оста инде. Түзегез! Бераз түзегез! Тагын дүрт көннән ярга чыгарсыз, сезнең өчен диңгез дә ачылыр, хәтта үзегез теләгәннән дә артыграк ачылыр, чөнки дүрт көннән соң Англия сездән котылачак.

Миледи кулларын кушырды да матур күзләрен гарешкә төбәп, фәрештәләрчә юаш тавыш һәм сабыр хәрәкәт белән:

— И ходаем! Минем кебек син дә кичерә күр бу бәндәне! — дип сөйләнеп куйды.

— Укын, укын, мәлгунь! — дип кычкырды барон.— Үзеңне гомердә дә гафу итмәячәк бер кеше кулына килеп эләккән булгач, синең догаң бигрәк тә ихлас инде!

Шулай дип, лорд Винтер чыгып китте.

Ул бүлмәдән чыккан чагында ярым ачык ишектән кемнеңдер текәлеп караганы чагылып китте һәм миледи шунда аңа күренмәс өчен тиз генә бер читкә тайпылган Фельтонны шәйләп калды.

Шуннан соң ул идәнгә тезләнде дә кычкырып дога укырга керешге.

— И ходаем! Ходаем! Минем нинди изге эш өчен газап чиккәнемне беләсең, шул газапларны күтәрерлек көч бир миңа,— диде миледи.

Әкрен генә ишек ачылды; гыйбадәт кылучы гүзәл ханым ишек шыгырдаганны ишетмәгәнгә салышты һәм аһ-зарлы бер тавыш белән аллага ялваруында дәвам итте:

— И кодрәтле ходай! И рәхим-шәфкатьле ходай! Шул бәндәнең яман ниятләре чынга ашуына юл куярсың микәнни?

Шуннан соң гына ул Фельтонның аяк тавышын ишеткәнлеген сиздерде. Тиз генә сикереп торды да, идәнгә тезләнеп гыйбадәт кылган чагында өстенә кеше килеп кергәнгә оялган кебек, кызарынып китте.

— Гыйбадәт кылган кешеләргә комачауларга яратмыйм мин, ханым, шуңа күрә, зинһар, минем аркада борчыла күрмәгез,— диде Фельтон җитди бер төс белән.

Миледи елаганнан беркадәр буылганрак тавыш белән:

— Ә нигә әле сез мине гыйбадәт кыла дип уйладыгыз? Хаталанасыз, мин гыйбадәт кылмадым,— диде.

— Ханым, тәңре каршында сәҗдә кылучыга комачаулык итәргә минем хакым бар дип уйлыйсызмы әллә сез? — диде Фельтон беркадәр йомшара төшеп, шул ук җитди төс белән.— Алла сакласын! Өстәвенә гаеп кылган адәмнәргә тәүбә итү лазем, кылган җинаяте нинди генә булса да, җинаятьче кеше ходайга йөз баглаган чагында минем өчен изге ул.

— Мин гаеп кылганмын! — диде миледи, ахыры заман көнендә газраилне дә коралсыз калдырырлык бер елмаю белән.— Гаеп кылганмын! Ходаем, шулаймы икәнен син яхшы беләсең. Мине гаепләнгән диегез, анысы хак, әмма сезгә ходай-

ның газап чиккән бәндәләрен яратуы, кайвакыт гаепсез кешеләрен хөкем итәргә юл куюы да мәгълүм бит.

— Җинаять кылганмы сез, әллә газап чигүче генәме — барыбер сез гыйбадәт кылырга тиешсез, мин үзем дә сезнең өчен гыйбадәт кылачакмын.

Миледи:

— О, гадел җан,— дип кычкырып җибәрде дә Фельтонның аягына егылды.— Тыңлагыз әле, моннан ары инде мин сездән яшерә алмыйм: мин көрәштә бирешмәскә, үз динемне ачыктан-ачык тотарга кирәк вакытта көчем җитмәс дип куркам. Тыңлагызчы өметсезлеккә төшкән бер хатынның гозерен. Сезне монда алдыйлар, ләкин хикмәт анда түгел, мин сездән бары тик бер генә яхшылык сорыйм, әгәр сез аны эшләсәгез, мин сезгә бу дөньяда да, теге дөньяда да яхшылык кына теләр идем!

— Ханым, минем башлыгым белән сөйләшегез,— диде Фельтон,— бәхеткә каршы, миңа кичерү хокукы да, җәзалау хокукы да бирелмәгән, андый җаваплы эшне ходай миннән зуррак кешегә йөкләгән.

— Юк, сезгә, сезгә генә йөкләгән ул аны! Минем һәлак булуыма, мәсхәрә ителүемә юл куйганчы, мине тыңлавыгыз хәерлерәк булыр.

— Ханым, әгәр сез андый хурлыкка лаек булгансыз, андый мәсхәрәгә дучар булгансыз икән, ходайның кушканына буйсынып, түзәргә кирәк.

— Ни сөйлисез сез? Һай, мине аңламыйсыз сез! Мәсхәрә ителү дип сез мине берәр төрле җәза, төрмә яисә әҗәлне күздә тота дип уйлыйсыздыр! Миңа төрмә дә, әҗәл дә берни түгел!

— Ханым, мин сезне аңламый башладым.

— Яки аңламаганга салышасыз,— дип куйды әсир хатын, икеләнгән сыман елмаеп.

— Юк, ханым, солдат намусым белән, христианлык иманым белән ант итеп әйтәм!

— Ничек инде! Лорд Винтерның миңа карата нинди ниятләре барлыгы сезгә мәгълүм түгелмени?

— Юк, мәгълүм түгел.

— Белмәвегез мөмкин түгел, сез бит аның ышанычлы кешесе!

— Минем беркайчан да ялган сөйләгәнем юк, ханым.

— Аһ, ул бит үзенең ниятләрен бөтенләй яшерми диярлек, аны сизүе бер дә кыен түгел!

— Ханым, мин бернәрсәне дә сизәргә-белергә тырышмыйм, мин бары тик үземә ышануларын гына көтәм, ә лорд Винтерның, сезнең алда әйткәннәрдән башка, миңа берни дә ышанып сөйләгәне юк.

— Димәк, сез аның булышчысы түгел? — дип, чын-ихлас бер тавыш белән кычкырып сорады миледи.— Димәк, сез аның минем өчен дөньядагы бер генә җәза белән дә чагыштырмаслык коточкыч хурлык хәзерләгәнен белмисез?

— Ханым, сез ялгышасыз. Лорд Винтерның андый яманлык

кылырга сәләтеннән килми,— дип кызарынып каршы төште Фельтон.

«Бик яхшы! Сүзнең ни хакында икәнлеген дә белми торып, шуны яманлык дип атый»,— дип уйланды миледи һәм кычкырып:

— Түбән җанлы кешенең дусты бөтенесенә дә сәләтле,— диде.

— Түбән җанлы кеше дип кемне атыйсыз? — дип сорады Фельтон.

— Англиядә мондый исемгә туры килә торган тагын башка берәр кеше бармыни?

Фельтон:

— Сез Джордж Вильерсны әйтәсезме? — дип кайтарып сорады һәм күзләре ялтырап китте.

— ...Мәҗүсиләр белән денсезләр аны герцог Бекингэм дип атыйлар,— дип өстәде миледи.— Кем турында әйткәнемне бик озак аңышмый торырлык бер инглиз Англиядә очрар дип башыма да китермәгән идем мин!

— Ходай аның өстенә дә кулын сузган, үзенә тиешле җәзасыннан качып котыла алмас ул,— диде Фельтон.

Ул герцогка карата бөтен инглизләрдә туган нәфрәтне генә әйтеп бирде,— католиклар аны хәтта ришвәтче, кан эчүче фахиш адәм дип, пуританнар исә иблис дип кенә атыйлар иде.

— И ходаем! И ходаем! — диде миледи.— Мин синнән ул әфәндегә тиешле җәзасын бир дип ялварганда, минем шәхси үчлектән чыгып сорамаганымны, бәлки бөтен бер халыкны коткарыр өчен гозерләгәнемне беләсең бит!

— Сез аны беләсезмени? — дип сорады Фельтон.

Миледи күңеленнән: «Ниһаять, бу миннән үзе сорый»,— дип уйлап куйды, мондый зур нәтиҗәгә шулай тиз ирешүенә бик нык сөенде.

— Мин аны беләмме! Әйе шул! Бәхетсезлегемә, гомерлек бәхетсезлегемә каршы, беләм шул мин аны!

Миледи, бик яман кайгыга төшкән кебек, кулларын угаларга-боргаларга кереште. Фельтон үзенең түземе бетеп барганлыгын сизде, ахры, берничә адым ишеккә таба атлады; аңардан күзен алмый карап торган әсир хатын сикереп торды да артыннан йөгереп килеп туктатты аны.

— Фельтон әфәнде, зинһар, рәхим-шәфкатьле булыгыз, тыңлагызчы үтенечемне! — дип кычкырды ул.— Пычак китерегезче миңа; барон, бер-бер яман хәл булудан куркып, миннән алган иде аны, чөнки минем пычак белән нишләргә теләвемне белә ул... О, әйтеп бетергәнемне генә көтегезче! Бер генә минутка пычак биреп торыгыз миңа, кызганыгыз мине, булыгыз рәхим-шәфкатьле!.. Менә мин сезнең аягыгызга егылдым! Ихластыр, минем сезгә бернинди усаллыгым юк! Ай аллам! Бердәнбер яхшы күңелле, миһербанлы, гадел кеше — сезне очраттым, шул кешене дошман күрәмме мин! Сез минем коткаручым дадыр әле, бәлки!.. Бер генә минутка, фәкать

бер генә минутка биреп торыгыз, мин аны сезгә шундук ишектәге тәрәзә аша кире кайтарам! Бер генә минутка биреп торыгыз, Фельтон әфәнде, сез минем намусымны саклап калачаксыз!

Фельтон, коты чыгып:

— Сезне үтерергә?! Сезне үтерергә?! — дип кычкырды, кулларын әсир хатынның кулыннан ычкындырырга да онытты.

— Үземне үзем фаш иттем,— дип пышылдады миледи, хәле киткән кебек, лып итеп идәнгә утырды.— Үземне үзем фаш иттем! Хәзер инде ул барысын да белә! Ай ходаем, харап булдым!

Фельтон, ни чара кылырга белмичә, баскан урынында хәрәкәтсез катып тора иде.

«Икеләнә әле, ихласлыгым җитмәде»,— дип уйлады миледи.

Шул вакыт коридордан кемнендер килгәне ишетелде: миледи моның лорд Винтер атлавы икәнен таныды. Фельтон да танып ишеккә таба китте.

Миледи аның артыннан ташланды.

— Минем бер сүземне дә әйтмәгез ул кешегә, югыйсә мин бетәм, сез, сез моны...— дип сөйләнде ул буылган бер тавыш белән.

Аяк тавышы якынлаша бирде, миледи сөйләшкәнебезне ишетерләр дип коты очып тынып калды һәм чиксез куркуга төшкән бер хәрәкәт белән матур кулын Фельтонның авызына куйды. Фельтон аны йомшак кына итеп этәреп җибәрүгә, миледи, китеп, диванга ауды.

Лорд Винтер, туктамыйча, ишек яныннан үтте, аяк тавышы ары китеп тынды.

Фельтон, үлек төсле агарынып, беравык бик игътибар белән тыңлап торды, шуннан соң, аяк тавышы тынгач, йокысыннан уянган кеше шикелле, тирән итеп бер сулады да тиз генә бүлмәдән чыгып китте.

Үз нәүбәтендә миледи да, тыңлап торып, Фельтонның аяк тавышы лорд Винтерга капма-каршы якка китүенә ышангач:

— Әһә! Хәзер инде син минеке! — дип куйды.

Шуннан соң чырае тагын караңгыланып китте.

«Әгәр ул баронга әйтсә, мин беттем,— дип уйланды.— Барон минем үземне үзем үтермәячәгемне белә, Фельтон алдында миңа пычак бирәчәк тә, Фельтон минем болай өзгәләнүемнең хәйләгә салышу гына икәнен күрәчәк».

Ул көзге каршына килеп үз-үзенә күз салды: аның әле моңарчы беркайчан да бу кадәр чибәр, сөйкемле булганы юк иде.

— Әйе, әйе! Әлбәттә, берни әйтмәячәк ул аңа,— дип сөйләнде миледи елмаеп.

Кич, аш китерелгәч, лорд Винтер килде.

— Галиҗәнап, сезнең минем янга кереп йөрүегез минем тоткынлыкның котылгысыз бер шартымы әллә? Сез шушылай үзегезнең кереп йөрүегез белән тудыра торган газаплардан мине коткара алмыйсызмы? — диде аңа миледи.

— Ничек инде ул, сөеклә сеңлем! — диде лорд Винтер.— Сез бит үзегез сөйкемле-матур авызыгыз белән өзелеп әйттегез: Англиягә фәкать сезне күреп сөенер өчен генә килдем, бик сагындым, шуның хакына диңгез авыруыннан да, җил-давылыннан да, әсирлектән дә куркып тормадым,, дидегез! Менә мин сезнең каршыгызда инде, күңелегез булсын! Өстәвенә, бу юлы минем керүемнең билгеле бер максаты да бар.

Миледи калтыранып куйды: Фельтон мине саткан икән, дип уйлады; гомерендә иң яман куркуын да, шатлыгын да бик күп кичергән бу хатынның йөрәге беркайчан да бу кадәр дөрселдәп типкәне булмагандыр.

Ул утырып тора иде. Лорд Винтер кресло алып, миледи янынарак килеп утырды, аннары кесәсеннән ниндидер кәгазь чыгарды да ашыкмый гына ачты аны.

— Менә карагыз! — дип сүзгә кереште ул.— Мин сезгә торыр өчен юллама сыман бернәрсә күрсәтмәкче идем, мин моны үзем яздым, киләчәктә ул тормышыгызда тәртип номеры булып хезмәт итәр, мин сезне дөньяда яшәтергә ризамын.

Шулай дигәч, күзен миледидан алды да кәгазьгә карап, кычкырып укый башлады:

— «...га алып китәргә боерык» — тәгаен кая икәнен күрсәтү өчен буш урын калдырылган,— диде лорд Винтер сүзеннән бүленеп.— Әгәр сез үзегез берәр җиргә китәргә телисез икән, әйтегез аны миңа, үтенечегезне үтәрмен, тик ул җир Лондонга бер мең мильдән дә якын булмасын. Ярый, яңадан укыйм: «Франция король дәүләтенең суды белән хурлык тамгасы салынып, җәза алганнан соң иреккә чыгарылган Шарлотта Баксон исемле кешене ...га алып китәргә боерык; ул, өч мильдән дә ары чыкмыйча, шунда яшәячәк. Качарга ниятләсә, үлем җәзасына дучар ителәчәк. Торырына һәм ашарына көненә биш шиллинг акча биреп барылачак».

— Бу боерык миңа кагылмый, андагы исем минеке түгел,— диде миледи салкын гына.

— Исем! Сезнең исемегез бармыни?

— Мин сезнең туганыгызның фамилиясендә йөрим.

— Ялгышасыз: минем туганым сезнең икенче ирегез генә булган, ә беренче ирегез исән әле. Шуның исемен әйтсәгез, мин аны Шарлотта Баксон урынына язып куям. Теләмисезме?.. Юк?.. Эндәшмисез?.. Яхшы алайса. Сез арестантлар исемлегенә Шарлотта Баксон дип языласыз.

Миледи һаман эндәшмәде, әмма аның бу юлы эндәшмәве хәйлә корудан түгел, бәлки куркып калуыннан иде: ул әлеге боерыкны хәзер үк гамәлгә ашырырлар дип уйлады; бүген кич белән үк утыртып алып китмәгәйләре дип курыкты. Әнә шулай бөтен өмет бетте дип кенә торганда, боерыкка әле кул куелмаган булуы күзенә чалынды.

Моны күрүгә шулхәтле сөенде ул — хәтта шатлыгын сиздермичә яшереп кала алмады.

— Әйе, әйе,— диде лорд Винтер, аңардагы бу үзгәрешне

күреп,— әйе, боерыктан имза эзлисез сез, боерыкка әле кул куелмаган булгач, өмет бөтенләй үк бетмәгән, дисез. Мине куркытыр өчен генә күрсәтәләр моны, дисез. Һәм бик ялгышасыз: иртәгә бу боерык лорд Бекингэмга җибәреләчәк, берсекөнгә аның имзасы куелып, печәте басылып кире кайтачак, аннары егерме дүрт сәгатьтән соң, сезгә ышандырып әйтә алам, гамәлгә ашырылачак. Сау булып торыгыз, ханым, минем сезгә әйтәсе сүзем шулар иде.

— Ә мин моны, галиҗәнап, явыз ният белән властьтан файдалану дип, уйдырма исем астында сөргенгә сөрү — кабахәтлек дип әйтәм сезгә.

— Дар агачына үзегезнең чын исемегез белән асылырга телисезмени, миледи? Никахка карата кылган җинаять өчен Англия законнары бик рәхимсез җәзага тартканлыгы сезгә мәгълүмдер бит. Турысын әйтеп сөйләшик: бу хурлыклы хәлгә минем исемем, дөресрәге, туганым исеме катнашса да, сездән бөтенләйгә котылу өчен, бөтен халык алдында фаш булуымнан да курыкмыйм.

Миледи җавап кайтармады, үлек чырае төсле агарынып кына китте.

— Ә, күрәм, сез бит ерак илләргә сәяхәт кылырга яратасыз. Бик яхшы, ханым, борынгы бер мәкаль әйтә: сәяхәт итү яшьләргә аң-тәрәккъыять бирә, ди. Валлаһи, ахыр чиктә, сез хаклы бит. Яшәү дигәнең — бик кадерле нәрсә шул. Шуңа күрә дә сез мине аннан мәхрүм итмәгәегез дип кайгыртам мин. Димәк, әлеге биш шиллинг мәсьәләсендә генә аңлашасы калды. Минем сезгә саран булып тоелуым да ихтимал, шулаймы? Сез үзегезнең сакчыларыгызны сатып алмагаегыз дип борчылам мин — сәбәбе шуннан. Хәер, аларның башын-күзен әйләндерергә сезнең бөтен чибәрлек тылсымнарыгыз үзегездә кала бит. Фельтон белән булган уңышсызлыгыгыз андый эштән күңелегезне сүрелдермәгән булса, файдаланып карагыз аннан.

«Фельтон мине сатмаган икән, алайса, өмет бөтенләй үк бетмәгән әле»,— дип уйлады миледи.

— Ә хәзергә сау булып торыгыз, ханым. Иртән мин атчабарымның китүен килеп әйтермен.

Лорд Винтер торып мыскылчан бер төстә баш иде дә чыгып китте.

Миледи иркен сулап куйды: алда әле аның дүрт көн вакыты бар, Фельтонның тәмам башын-күзен әйләндерү өчен дүрт көн бик җиткән иде.

Ләкин аның күңеленә, лорд Винтер боерыкка кул куйдыру өчен Фельтонның үзен җибәрү ихтимал бит, дигән куркыныч бер уй да килде, ул чагында Фельтон миледи кулыннан ычкыначак, әсир хатынга исә нияте уңышлы булып чыксын өчен тылсымнарының тәэсире туктаЛып калмаска тиеш иде.

Шулай да, әйткәнебезчә, бернәрсә милединың күңеленә тынычлык бирде: Фельтон аны лорд Винтерга сатмаган иде.

Әсир хатын, лорд Винтерның куркыту-янавыннан йогып кал-

ган борчуын сиздермәскә тырышып, өстәл янына ашарга килеп утырды.

Аннары, кичәге кебек, идәнгә тезләнде дә кычкырып дога укырга кереште. Кичәге кебек ук, ишек төбендәге солдат, йөрүеннән туктап, тыңлап тора башлады.

Озакламый миледи сакчы солдат атлавына караганда җиңелрәк аяк тавышы ишетте; бу тавыш, коридорның аргы башыннан бирегә таба якыная-якыная, ишек төбендә туктап калды.

«Ул»,— дип уйлады миледи.

Һәм кичә Фельтонны таң калдырган гимнны җырлап җибәрде.

Аның көчле, саф тавышы моңарчы булмаганча бик моңлы һәм хисле булса да, ишек ачылмады. Миледи ишектәге тәрәзәгә елт кына күз салды һәм шунда тыгыз рәшәткә аша егетнең уттай янган күзләрен күргән сыман тоелды; ләкин миледи моның чыннан да шулай булганмы, әллә үзенә шулай тоелган гынамы икәнен тәгаен белә алмады; бу юлы егетнең бүлмәгә керми калырга көче-түземе җитте.

Ләкин миледи җырлавыннан туктап, бераз гына вакыт узуга, тирән итеп көрсенгән тавыш ишетә сыман тоелды; шуннан соң аның ишек төбенә килгән баягы аяк тавышы, китәргә теләмәгән шикелле, әкрен генә китеп барды.

## *XXV*

## *ТОТКЫНЛЫКНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ КӨНЕ*

Иртәгесе көнне Фельтон, миледи янына килеп кергәч, әсир хатынның кулына бау тотып креслода басып торганын күрде — миледи батист яулыкны тасма-тасма итеп аерган да бөтереп, оч-очларын бер-берсенә ялгаган иде; Фельтон кергән чагында ишек шыгырдаганны ишеткәч, миледи елт кына креслодан сикереп төште дә кулындагы үзе ясаган бауны артына яшереп маташкан булды.

Егетнең чырае гадәттәгедән дә аграк иде, йокысызлыктан кызарган күзләре аның төнне бик борчылып чыкканлыгын әйтеп тора иде.

Әмма кыяфәтенә караганда аны иң каты бер кырыслык белән коралланган дип уйларлык иде.

Фельтон әкрен генә атлап креслода утырган миледи янына килде, әҗәл бавының очын күтәреп,— миледи бауны ялгышмы, әллә юриме яшереп җиткермәгән иде,— салкын гына тавыш белән сорады:

— Нәрсә бу, ханым?

— Бумы? Бернәрсә дә түгел,— диде миледи ямансылаган бер төс белән елмаеп (мондый төсне ул елмаюына бик оста чыгара белә иде),— эч пошу — тоткыннарның явыз дошманы ул. Эчем пошты да шуннан менә шушы бауны иштем.

Фельтон милединың креслосы турысындагы стенага күз салды һәм өстәрәк кием яки корал элеп кую өчен кагылган алтынлаган чөй күрде. Калтыранып куйды, әсир хатын моны, әлбәттә, күрми калмады: ул аска карап кына утырса да, бернәрсәне дә күзеннән ычкындырмый иде.

— Креслога басып нишләдегез? — дип сорады Фельтон.

— Анысы сезгә нигә кирәк?

— Беләсем килә,— диде Фельтон.

— Сорамагыз, без христианнарга алдашу гөнаһ икәнлеген беләсез бит.

— Ул чагында сезнең ни эшләгәнегезне, дөресрәге — нәрсә эшләргә җыенганыгызны мин үзем әйтәм: сез күңелегездә йөрткән һәлакәтле ниятегезне гамәлгә ашырырга теләгәнсез. Беләсездер, ханым: ходай алдашуны тыю белән бергә, мордар китүне тагы да катырак тыя бит.

— Ходай үзенең бер бәндәсе нахакка җәберләнгәнен, ул бәндәсе я мордар китәргә, я мәсхәрә ителергә тиеш булганлыгын үз күзе белән күреп торганда, ихластыр, мордарлыгы өчен аны кичерер ул, мондый чакта мордар китү — газапланып үлү була бит,— диде миледи үз сүзенә нык ышанган бер тон белән.

— Я сез арттырасыз, я әйтеп бетермисез. Ханым, алла хакы өчен, барысын да әйтеп сөйләшегез әле.

— Үземнең нинди бәхетсезлекләргә төшүемне сөйләсәм, сез аны уйдырма дип санар идегез, уйларымны уртаклашсам, мине җәберләүче кешегә җиткерер идегез,— юк, булмый, галиҗәнап. Өстәвенә гаепле дип саналган бичара бер хатынның исән калу-калмавы сезнең өчен нәрсә ул? Сез бит минем гәүдәм өчен генә җаваплы, шулаймы? Сез минем мәетемне күрсәтсәгез, моның мин икәнлеген расласалар, сездән шул җиткән, бәлки әле, шуның өчен сез икеләтә бүләк тә алырсыз.

— Минме, ханым, минме?! — дип кычкырып җибәрде Фельтон.— Мине сезнең үлемегез өчен бүләк алырга риза дип уйлыйсызмы?! Сүзегезне уйламый сөйлисез!

— Фельтон, комачауламагыз миңа, комачауламагыз,— диде миледи рухлана төшеп.— Солдатның һәркайсы дәрәҗәгә омтылырга тиеш, дөресме? Сез инде — лейтенант, ә минем табутым артыннан барганда капитан чинында булырсыз!

Милединың бу сүзләренә шаккатып калган Фельтон:

— Ходай белән бәндәләр каршында минем өскә бу кадәр җаваплылык салырга мин сезгә нинди яманлык эшләгән?! — дип сөйләнеп куйды.— Берничә көннән, ханым, сез бу замоктан китәсез, шуннан соң мин сезнең исәнлегегез өчен җавап бирмәячәкмен, аннары инде,— диде ул көрсенеп куеп,— аннары үләсезме, каласызмы — анысы үз эшегез.

Миледи, җан гарьлегенә түзеп торырлык башка көче калмаган кебек, кычкыра төшеп әйтте:

— Димәк, сез, бик диндар кеше, бик гадел дип саналган кеше, бары тик бер генә нәрсәне — минем үлүемдә үзегезне

гаепләмәүләрен, минем үлемем сезне бер дә борчымавын гына телисез!

— Мин сезне исән сакларга тиешмен һәм исән саклап калачакмын да.

— Ә сез үзегезнең нинди вазифа башкарганыгызны беләсезме? Мин хәтта гаепле булган тәкъдирдә дә сезнең болай итүегез рәхимсезлек булыр иде; әгәр мин гаепле булмасам, сез үзегезнең мондый тотышыгызны ничек дип атар идегез, ходай аны ничек дип атар икән?

— Мин, ханым, солдат кеше, нинди боерык бирсәләр, шуны үтим.

— Мәхшәр көнендә ходай сукыр рәвештә буйсынып эш иткән палачларны гадел булмаган хөкемчеләрдән аерып карар дип уйлыйсызмы? Сез минем үз-үземне үтерүемне теләмичә, мине хараһ итәргә җыенучы кешенең теләгән үтәүчегә әйләнәсез.

— Кабатлап әйтәм,— диде Фельтон икеләнә башлап,— сезгә бернинди куркыныч юк, мин үзем өчен ничек җавап бирсәм, лорд Винтер өчен дә шулай җавап бирә алам.

— Акылсыз! — диде миледи кычкырып.— Иң акыллы, иң тәкъва кешеләр үз-үзләренә дә ышанмаган бер вакытта икенче бер кешегә ышанып яшәүче адәм акылсыз бер мәхлук ул; иң көчле, иң бәхетле кеше ягына басып, көчсезләрне, бәхетсезләрне җәберләүче адәм акылсыз адәм ул!

Фельтон, бу сүзләрнең дөреслегенә күңеленнән ышанып, әкренрәк тавыш белән:

— Мөмкин түгел, ханым, мөмкин түгел,— диде.— Биредә тоткын чагыгызда сез минем булышлыгым белән иреккә чыга алмыйсыз, исән чагыгызда минем булышлыгым белән үлә дә алмыйсыз.

— Шулай, мин җанымнан да кадерлерәк нәрсәмне югалтачакмын,— диде миледи кычкыра төшеп,— минем кешелек намусымны таптаячаклар, һәм сезне, Фельтон, үземнең мәсхәрә һәм хур ителүем өчен ходай белән кешеләр каршында җаваплы санаячакмын!

Бу юлы инде Фельтон, никадәр генә хиссез-коры булмасын яки шундый булырга тырышмасын, үзен буйсындыра башлаган астыртын бер йогынтыга каршы тора алмады: фәрештә кебек саф, гүзәл бу хатынның әле күз яшьләрен түгеп елавы, әле куркыткан-янаган булуы, шул ук вакытта аның сөйкемле матурлыгын да, кайгы-хәсрәтенең үзенә бик нык тәэсир итүен дә тоеп тору хыялый бер кеше өчен, сукыр дини тойгылардан түнгән акыл өчен, бары алланы гына уйлаган, бөтен кешене дошман күргән күңел өчен — болар барысы берьюлы артык күп иде шул.

Миледи аның бу аптырашын сизми калмады, фанатик егетнең канында кайнаган капма-каршы тойгылар ялкынын, аңыннан тыш, күңеле белән тойды; дошманының чигенгәнен күреп, аның өстенә гайрәт белән ташланган оста гаскәр башы кебек,

ул, борынгы жрица шикелле гүзәлләнеп, христиан диненең саф кызы кебек рухланып торып басты; чәчләре таралып китеп, муены ачылып калды, күзләрендә пуритан егетнең хисләрен чуалткан әлеге очкыннар кабынды; бер кулы белән изү турыларын каплаштырып, икенчесен алга сузган килеш егеткә таба атлады да кайвакыт ярсу дәртле, дәһшәтле төсмерләргә дә керә торган матур тавышы белән җырлап җибәрде:

Ыргытыгыз мине Ваал * авызына,
Ташлагыз арслан өеренә.
Тәңре тотар сезне!.. Ялвардым мин аңа
Аваз салып упкын төбеннән.

Шушындый гаҗәп-сәер мөрәҗәгать вакытында Фельтон көтелмәгән бу хәлдән шаккатып калды.

— Кем буласыз сез, кем сез? — дип кычкырды ул, ялварып учларын сузган килеш.— Күктән индегезме, тәмугтан килдегезме, фәрештәме сез, әллә иблисме, исемегез Элоамы, әллә Астартмы?

— Танымыйсыңмыни мине, Фельтон? Мин фәрештә дә, иблис тә түгел, шушы дөньяның бер кызымын, диндәш туганың, менә шул.

— Әйе! Әйе! Моңарчы шикләнә идем әле, хәзер ышанам инде.

— Үзең ышанасың, ә үзең лорд Винтер дигән шул Велиал токымының булышчысы! Үзең ышанасың, ә үзең мине дошманнарым кулында, Англия дошманы, ходай дошманы кулында калдырасыңмы? Үзең ышанасың, ә үзең мине дөньяны денсезлек һәм бозыклык белән тутырып әшәкеләндерүчеләргә, сукырлар герцог Бекингэм дип, ә динлеләр антихрист дип атаган кабахәт Сарданапалга сатасың.

— Мин сезне Бекингэмга сатам?! Мин?! Ни сөйлисез сез?

— Күзе барлар күрмиләр! Колагы барлар ишетмиләр! — диде миледи кычкыра төшеп.

— Әйе, әйе,— диде Фельтон һәм, соңгы шиген дә тамыры белән йолкып ташларга теләгәндәй, маңгаендагы тирне кулы белән сыпырып төшерде.— Әйе, төшемдә ишеткән изге тавышны таныйм. Әйе, һәр көнне яныма килеп, йокы белмәгән җаныма кычкырып: «Сук-бетер, коткар Англияне, үз-үзеңне коткар, чөнки син ходайның ачуын басмыйча үлеп китәчәксең!» — дип әйтүче фәрештәнең йөз чалымнарын таныйм. Сөйләгез, сөйләгез, хәзер мин сезне аңлыйм! — диде Фельтон, кычкыра төшеп.

Милединың күзләрендә, ялт иткән яшен уты кебек, куркыныч бер сөенеч чаткысы чагылып китте.

Бу яман бер сөенеч нуры ялт итеп кенә алса да, Фельтон аны күреп, калтыранып куйды, гүяки шул нур бу хатынның бөтен күңел төпкелен яктыртып җибәрде кебек.

Фельтон кинәт шунда милединың тылсымлы чибәрлеге һәм беренче тапкыр кызыктырырга маташуы хакында лорд

* Борынгы Сүриядәге сами кабиләләрендә корбан сорый торган бер алла.

Винтерның кисәтүен исенә төшерде; бер адым арткарак чикте дә аңа караган килеш башын аска иде; шушы сәер затның сихеренә бирелгән кебек, ул аннан күзен ала алмады.

Миледи, үзенең зирәклеге аркасында, егетнең ни сәбәпле икеләнеп калуын дөрес аңлады. Тыштан ул дулкынланган-әсәренгән сыман күренсә дә, боз кебек салкын канлылыгын бер мизгелгә дә җуймады. Фельтон яңадан телгә килсә, миледины әлегәчә әсәренгән рухта сөйләшергә мәҗбүр итәр, алай дәвам иттерү исә чамадан тыш кыен булыр иде, шуңа күрә ул, хатын-кыз көчсезлеге аның рухын-дәртен алган кебек, кулларын аска төшерде.

— Юк, Ветилуяны Олофернннан азат итүче Юдифь була алмыйм мин,— диде миледи.— Тәңренең кылычы минем кулым өчен артык авыр шул. Бу хурлыктан миңа үлеп котылырга, газаплы үлем белән җанымны коткарырга ирек бирегезче. Мин сездән, җинаять кылган бер кеше кебек, азатлык та, мәҗүси кебек, үч алуны да сорамыйм. Үләргә ирек кенә бирегез, менә шул. Мин сездән алдыгызга тез чүгеп, ялварып сорыйм: миңа үләргә генә ирек бирегезче, минем соңгы сулышым коткаручы кешемә рәхмәтем булыр.

Шушы ялварган-тилмергән мескен тавышны ишетеп, кыюсыз, кызганыч күз карашын күреп, Фельтон тагын аның янына килде. Гүзәл хатын егет каршында әкренләп-әкренләп яңадан үзенең тылсымлы рәвешенә керде, үз теләге белән әле күрсәтә, әле яшерә торган бу тылсымын аның гүзәллеге, юашлыгы, күз яшьләре һәм бигрәк тә иң зарарлы тойгы булган мистик ләззәтнең күңелне яулый торган матурлыгы тудыра иде.

— Үзегезнең корбан икәнлегегезгә ышандыра алсагыз да, мин сезне фәкать кызгана гына алам шул! — диде Фельтон.— Лорд Винтер сезнең бик зур гаепләрегез бар ди бит. Сез христиан, минем диндәш туганым. Сез минем күңелемә ошыйсыз — минем моңарчы гомеремдә, үземә яхшылык итүче кешемнән башка, беркемне яратканым, хыянәтчеләр һәм монафикъ адәмнәрдән башка беркемне очратканым булмады. Әмма сез, ханым, шундый гүзәлсез, карап торуга шундый гаепсез-гөнаһсыз булып күренәсез,— лорд Винтер үзегезне шулай әзәрлекләгәч, сез берәр ярамаган эш эшләгәнсездер!

— Күзе барлар күрми, колагы барлар ишетми,— дип кабатлады миледи, тавышына тәкатьсез бер кайгы төсмере салып.

— Алай булгач, сөйләгез соң, сөйләгез! — дип кычкыра төшеп эндәште офицер егет.

— Сезгә үземнең ким-хур булуымны ышанып сөйлимме! — диде миледи кычкыра төшеп, оялуыннан битләре кызарып китте.— Берәүнең кылган җинаяте еш кына икенче берәү өчен хурлык була... Мин, хатын-кыз буларак, үземнең хурлыкка калуымны сез ир кешегә сөйлиммени?! Ай! — диде миледи, оялып, матур күзләрен кулы белән каплады.— Ай, беркайчан да, беркайчан да сөйли алмаячакмын мин аны.

— Миңа, туганыгызга дамы? — диде Фельтон.

Миледи аңа озак кына карап торды, офицер егет аның бу карашын икеләнеп торуы дип аңлады; чынлыкта исә милединың бу карашы егетне күзәтеп торуын һәм сихерләргә теләвен генә күрсәтә иде.

Фельтон, ялварып сораган кебек, кулларын сузды.

— Яхшы алайса, туганыма ышанып сөйләп бирәм! — диде миледи.

Шул минутта лорд Винтерның аяк тавышы ишетелде, тик бу юлы инде милединың усал кайнагасы кичәге шикелле ишек яныннан гына узып китмәде, бәлки туктап, сакчы белән бераз сөйләшеп торды; аннары ишек ачылды да бусагада лорд Винтер үзе күренде.

Ул сакчы белән сөйләшеп торган арада Фельтон бер читкәрәк тайпылды, лорд Винтер бүлмәгә килеп кергәндә инде Фельтон әсир хатыннан берничә адым читтәрәк басып тора иде.

Барон ашыкмыйча әкрен генә керде дә сынаган бер төс белән әсир хатынны һәм егетне күздән кичерде.

— Нишләптер озак торасың син монда, Джон,— диде ул.— Әллә бу хатын сезгә үзенең кылган җинаятьләрен сөйлиме? Алай булса, әңгәмәгезнең бу кадәр озакка сузылуы бер дә гаҗәп түгел.

Фельтон калтыранып куйды, һәм миледи, каушап калган бу пуританга ярдәм итмәсәм — беттем, дип уйлады.

— Ә! Әсирегез кулыгыздан ычкынмагае дип куркасыздыр! — диде ул.— Тугрылыклы төрмәчегездән мин әле генә рәхим-шәфкать күрсәтүен сорадым — нәрсә сораганымны әйтсен.

— Рәхим-шәфкать сорадыгызмыни? — диде барон шиккә төшеп.

Егет уңайсызланып кына:

— Әйе, милорд,— дип раслады.

— Нинди рәхим-шәфкать инде ул? — дип сорады лорд Винтер.

— Миннән пычак сораган иде. Бер минуттан ишектәге тәрәзә аша кире кайтарырга сүз биргән иде,— диде Фельтон.

— Берәр кеше качып ятмыйдыр ич монда, бу сөйкемле ханым кемне чәнчеп үтерергә җыена икән соң? — диде лорд Винтер кимсетүле, мыскылчан бер тавыш белән.

— Монда мин тоткынлыкта ятам,— диде миледи.

— Мин сезгә Американы яки Тайбернны сайлау мөмкинлеге бирдем, Тайбернны сайлагыз, миледи: ихластыр, пычакка караганда бау ышанычлырак булыр,— диде лорд Винтер.

Фельтонның төсе агарынып китте, егет бер адым алга табарак атлап куйды, үзе бүлмәгә килеп кергән чагында милединың кулына бау тотып торганын хәтерләде.

— Сүзегез хак, мин ул турыда уйладым инде,— диде миледи һәм буылган бер тавыш белән: — Тагын бер уйлармын әле,— дип өстәде.

Фельтон бөтен тәне дер-дер калтырануын тойды: аның болай калтыранганын лорд Винтер да сизде, ахры.

— Моңа ышанма, Джон,— диде.— Джон дустым, мин сиңа бу эшне ышанып тапшырдым, бик сак-уяу бул, мин сине кисәтеп куйдым! Хәер, түз, бирешмә, балам, тагын өч көннән соң без бу заттан котылабыз, мин озаткан җирендә инде ул беркемгә дә зарар кыла алмас.

— Ишетәсеңме?! — дип кычкырып эндәште миледи. Моны ул шулай барон аны аллага ялвара икән дип уйласын өчен эшләде, Фельтон исә миледины үзенә эндәшә дип аңлады.

Фельтон башын иеп уйга калды.

Барон офицерны култыклап алды да аны ишеккә таба ияртеп китте, үзе һаман, бүлмәдән чыгып киткәнче, башын артка борган килеш, миледидан күзен алмады.

Болар чыгып ишек ябылгач, әсир хатын: «Минем бу эшемдәге уңышым үзем уйлаганча ук түгел икән әле,— дип уйланды.— Винтер ахмакларча гадәтен ташлап, бик зур уяулык күрсәтә башлаган. Үчлек дигәнең менә шундый була шул ул, кешенең гадәт-холыкларын үзгәртә! Ә Фельтон... Фельтон икеләнә! Һай, теге каһәр төшкере д'Артаньян шикелле түгел шул ул. Пуритан егете гыйффәтле кызларны гына ярата шул, өстәвенә, кулларын гыйбадәт кылгандагы төсле итеп куйган чагында гына ярата. Мушкетер егет хатын-кызны кочагына алып ярата».

Шулай да миледи Фельтонның яңадан кергәнен түземсезлек белән көтте: бүген ул аның белән көрешми калмаячагына шикләнми иде. Ниһаять, шушы хәлләрдән соң бер сәгать чамасы узгач, миледи ишек төбендә әкрен генә сөйләшкән тавыш ишетте, шуннан соң озакламый бүлмә ишеге ачылып китеп, аның каршына Фельтон кереп басты.

Егет бүлмәгә тиз-тиз керде, ишекне яртылаш ачык калдырды, миледига «эндәшмәгез» дип кенә ишарә ясады: төсеннән аның бик нык борчылган булуы сизелеп тора иде.

— Миннән ни кирәк сезгә? — дип сорады миледи.

— Карагыз әле,— диде Фельтон әкрен генә,— минем сезнең янга керүемне беркем белмәсен, сөйләшүебезне беркем тыңлап тормасын дип, сакчыны моннан җибәрдем мин. Барон миңа әле генә коточкыч бер хәл сөйләде.

Миледи гөнаһсыз бер корбан сыман елмаеп куйды, башын чайкады.

— Я сез бер иблис, я барон миңа яхшылык итүче, атам кебек кешем — коточкыч бер залим,— диде Фельтон.— Мин сезне нибары дүрт кенә көн беләм, ә аны инде ике ел яратам. Шуңа күрә минем сезнең ике арагызда икеләнеп калуым бер дә гаеп түгел. Сез минем әйткәннәремнән курыкмагыз, миңа сезнең дөрес сөйләвегезгә ышанырга кирәк. Бүген, төн уртасы авышкач, мин сезнең янга килермен, шунда сез мине ышандырырсыз.

— Юк, Фельтон, юк, туганым,—диде миледи,—сез артык зур корбан бирәсез, сезнең өчен аның нинди нәтиҗәсе булуын аңлыйм мин. Юк инде, беттем мин, минем белән бергә үзегезне дә

карап итмәгез. Минем үлемем яшәвемнән мәгънәлерәк булыр, һәм телсез мәет тоткын хатынның сүзенә караганда күбрәк ышандырыр сезне.

— Туктагыз, ханым! — дип кычкырып җибәрде Фельтон.— Миңа андый сүз сөйләмәгез! Мин сездән үз-үзегезне үтермәячәгезгә вәгъдә алырга, изгеләр белән ант иттереп сүз бирдерергә килдем.

— Вәгъдә бирә алмыйм,— диде миледи.— Минем өчен ант бик кадерле нәрсә ул, әгәр сүз бирәм икән, мин ул сүземне тотарга тиеш булам.

— Алайса, һич булмаса, без яңадан күрешкәнче, бераз көтәргә, үз-үзегезгә кул салмаска сүз бирегез. Инде минем белән күрешкәннән соң да сез ул ниятегездән кире кайтмасагыз, ул чагында берни кылып булмый, сезнең үз ихтыярыгыз — теләсә нишләгез, сез сораган теге коралны мин үзем китереп бирермен.

— Ярар алайса, сезнең хакка көтәм.

— Ант итегез.

— Тәңребез белән ант итәм. Канәгатьме сез?

— Яхшы, киләсе төнгә кадәр.

Фельтон шулай диде дә тиз генә бүлмәдән чыгып ишекне япты, посттагы сакчыны алмаштырган кебек, кулына сөңге тотып, коридорда басып тора башлады.

Солдат килгәч, Фельтон коралны аңа кире бирде.

Миледи ишектәге кечкенә тәрәзәгә килеп, Фельтонның шашынып-шашынып чукынганын һәм, сөенеченнән нишләргә белмичә, коридор буйлап китеп баруын күреп калды.

Мыскылчан, явыз бер кыяфәттә елмаеп, урынына кире кайтты, әле генә үзе ант иткән, әмма инанмаган тәңресе исемен кабатлады.

— Минем тәңремме? — дип сөйләнде ул.— Акылсыз бер фанатик! Минем тәңрем — мин үзем ул һәм миңа үзем өчен үч алырга ярдәм итүче кеше.

## XXVI

## ТОТКЫНЛЫКНЫҢ БИШЕНЧЕ КӨНЕ

Миледи инде яртылаш җиңү ләззәтен кичерә, ирешкән уңышы бермә-бер аның көчен арттырып җибәргән иде.

Моңарчы әдәпле сарай тәрбиясе чибәр хатын-кыз тылсымына җиңел бирелүчән ирләрне милединың җәтмәсенә бик тиз эләктерткән чакларда андый уңышка ирешүе әллә ни кыен булмый торган иде; миледи шулкадәр чибәр иде — ирләрне кулга төшерүдә бернинди каршылыкка очрамый һәм шулхәтле җитез-тапкыр иде — җан-рух тудыра торган киртәләрне ул җиңел генә атлап уза иде.

Әмма бу юлы аңа ирлек тойгылары үлгән хиссез, йомык һәм кыргый бер шәхес белән эш итәргә туры килде; дин һәм каты дини күнекмәләр Фельтонны гадәттәге хатын-кыз кызык-

тыруына гына бирелми торган бер кеше иткән иде. Бу хыялый башка шундый зур планнар, шундый фетнәчел уй-теләкләр кереп тулган — анда тән ләззәтенә яисә күңел төшеп ратуга, ягъни эшсез яшәү җирлегендә туа һәм әхлакый бозыклык тәэсирендә үсә торган мәхәббәткә бернинди урын калмаган иде. Миледи монда үзенә бер юл ачты: яхшы күңелле бер кеше булып күренергә тырышып үзенә карата начар фикердә торган кешенең карашын үзгәртте, чибәрлеге-сөйкемлелеге белән исә саф тойгылы һәм пакь җанлы кешенең күңелен яулап алды. Ниһаять, өйрәнү өчен үзенә табигать һәм дин китереп биргән иң буйсынмас зат белән булган тәҗрибәсендә ул моңарчы үзе дә белеп җиткермәгән көч һәм сәләтен бөтен иңе-колачына җәеп җибәрде.

Тик шулай да бу кичне ул язмышыннан да, үз-үзеннән дә ничәмә-ничә тапкыр өмет өзде; дөрес анысы, ходайга ялвармады, аның каруы явыз бер көчнең, кеше тормышының бөтен вак-төяге белән эш итүче, гарәп әкиятендә әйтелгәнчә, үлеп беткән бер дөньяны бер бөртек анар орлыгы белән дә тергезүче кодрәтле көчнең ярдәм итәчәгеннән өмет өзмәде.

Миледи Фельтонның килеренә бик яхшылап хәзерләнде, аның белән көрешкәч ничек-ничек итәргә тиешлеген җентекләп уйлап куйды. Ул үзенә нибары ике генә көн калып баруын һәм боерыкка Бекингэм кул кую белән (боерыкка милединың чын исеме язылмагач, Бекингэм аңа ике дә уйламыйча кул куячак, чөнки ул нинди хатын турында сүз барганлыгын белмәячәк), әйткәнебезчә, боерыкка кул куелу белән, барон миледины шундук ерак юлга озатачак; миледи шулай ук сөргенгә хөкем ителгән хатын-кызларның ирләр күңелен яулый торган көчле чаралары, җәмгыять карашынча инсафлы саналган хатын-кызларныкы белән чагыштырганда, күп өлеш азрак икәнен дә белә — соңгыларының чибәрлеге югары җәмгыятьнең зиннәте эчендә тагы да арта төшә, ул мода теле белән мактала һәм аристократик нәселнең тылсымлы алтын нурларына манчыла. Кимсетүле, хурлыклы җәзага хөкем ителү хатын-кызның матурлыгын бетермәсә дә, яңадан көч-кодрәткә ирешүдә үтеп булмаслык бер киртәгә әйләнә. Чын-чыннан сәләтле кешеләр кебек, миледи үзенең табигатенә, табигать биргән сыйфатларына нинди мохит уңайлырак икәнен бик яхшы белә иде. Ярлылык аны читкә тибәрә, ким-хурлык исә биеклегенең өчтән ике өлешеннән мәхрүм итә иде. Миледи королевалар арасында гына королева иде; хакимә булу өчен теләкләренең үтәлгәнен тоеп яшәргә тиеш ул. Түбән затларны үзенә буйсындырып яшәү аның өчен ләззәт булудан бигрәк ким-хурлык кына иде.

Әлбәттә, сөрелгән җиреннән кире әйләнеп кайтыр иде ул, монысына тамчы да шикләнми, ләкин ул сөргенлек күпмегә сузылыр соң? Кешенең биеклеккә үрләми калган көннәре миледи кебек хакимлек яраткан эшчән зат өчен бәхетсез көннәр булып тоела иде; ә менә кешенең аска таба тәгәрәгән көннәрен, нинди сүз табып, ни дип атарга соң?! Бер ел, ике ел, өч

ел югалту,— бик күп гомер югалту дигән сүз бит бу; д'Артаньян үзенең дуслары белән кылган яхшылыклары өчен королевадан бүләк алып, шат-рәхәт яшәп яткан чакта кайту дигән сүз! Болар барысы миледи шикелле хатын-кыз күңеле күтәрә алмый торган газаплы-авыр уйлар иде. Хәер, милединың йөрәгендә кайнаган давыл аның көчен бермә-бер арттырса, һәм әгәр бер генә минутка физик көче акыл көченә тиңләшә алса, зинданының диварларын ватып-җимереп тә чыгар иде ул.

Аны тагын бик нык хафага салганы — кардинал турындагы уйлары иде. Кешегә ышанмыйча, гел шикләнеп карый торган ул тынгысыз кардинал ни дип уйларга, милединың хәбәр-хәтерсез югалуын ничек аңларга тиеш булыр? Кардинал бит аның хәзерге көндәге бердәнбер терәге-таянычы, бердәнбер химаячесе генә түгел, бәлки киләчәктә бәхетенә ирешү һәм үч кайтаруда төп коралы бит. Миледи бик яхшы белә аны, уңышсыз сәяхәтеннән әйләнеп кайткач, мине төрмәгә яптылар, бик күп газап-җәбер күрдем дип акланып маташуы урынсыз булачагын бик яхшы белә; кардинал, көчле власть һәм көчле акыл иясе буларак, скептикларча тыныч кына көлеп әйтер: «Эләгәсегез калмаган!» дияр.

Мондый чакларда миледи бөтен көч-куәтен җыеп, күңеленнән Фельтон исемен генә тәкрарлый — Фельтон ул төшкән җәһәннәмнең төбенә үтеп керә торган бердәнбер нур-өмет чаткысы иде шул; һәм миледи, буыннарын бер җәеп, бер җыеп көчен сынап караган елан кебек, Фельтонны алдан ук зирәктапкыр хыялы белән урый башлады.

Әмма вакыт дигәнең уза тора, сәгатьләр бер-бер артлы үтешли генә чаңга кагылып китәләр кебек, һәм бакыр телнең даң-доң итеп сугуы әсир хатынның йөрәгенә тиеп яңгырап-иңрәп ала иде. Сәгать тугызда, гадәтенчә, лорд Винтер килеп керде, тәрәзә белән тимер рәшәткәләрне карады, идән, стена, камин һәм ишекләрне тикшереп чыкты, һәм ул шулай озаклап, җентекләп караган арада миледи да, ул да бер сүз эндәшмәделәр.

Һичшиксез, хәлнең бик җитдиләшкәнен, файдасызга сүз сөйләп, бушка ярсынуның мәгънәсе юк икәнлеген икесе дә аңлый иде.

— Юк, юк, бу төнне кача алмыйсыз әле сез! — диде барон чыгып киткән чагында.

Сәгать унда Фельтон ишек төбенә сакчы куярга килде, миледи аны аяк атлавыннан ук таныды. Хәзер инде ул аны сөяркә хатын сөйгән егетен аяк атлавыннан ук сизгән кебек таный, тик миледи йомшак характерлы бу фанатикны өнәми, дошман күрә иде.

Сөйләшенгән вакыт әле җитмәгән, бүлмәгә Фельтон да кермәгән иде.

Ике сәгатьтән соң, төн уртасында, сакчыны алмаштырдылар.

Хәзер инде сөйләшенгән вакыт җиткән, миледи егетне түземсезләнеп көтә башлаган иде.

Коридорда яңа сакчы йөренергә тотынды.

Бер ун минуттан Фельтон килеп җитте.

Миледи сагая калды.

— Ишетәсеңме, бернинди сылтау белән дә шушы ишек яныннан беркая китмә,— диде егет сакчыга,— узган төнне бер солдатка бер генә минутка постыннан китеп торганы өчен дә милордның җәза биргәнлеген беләсең бит, югыйсә ул сакчыны мин үзем алмаштырып торган идем.

— Әйе, мин аны беләм,— диде солдат.

— Бик ныгытып сакларга кушам. Ә мин кереп, ул хатынның бүлмәсен тагын бер тапкыр карап чыгам: аның үз-үземә кул салам дигән яман уе булмагае, миңа аны күзәткәләп торырга кушылды,— диде Фельтон.

— Бик яхшы. Тәкъва пуритан менә алдаша да башлады,— дип пышылдады миледи.

Солдат көлеп кенә куйды.

— Ах, шайтан, сезгә инде андый боерыктан зарлану гөнаһ булыр, лейтенант әфәнде, милорд аның түшәгенә дә күз салырга кушкан булса — бигрәк тә.

Фельтон кызарынып китте; башка вакыт булса, солдатны болай шаяртканы өчен ул каты гына орышып та алган булыр иде, тик бу юлы аның намусы баш калкыткан, андый сүз әйтә алырлык хәлдә түгел иде.

— Мин чакырсам — керерсең. Берәрсе килсә дә, мине чакырырсың,— диде ул.

— Тыңлыйм, лейтенант әфәнде,— диде солдат.

Фельтон миледи янына керде. Миледи урыныннан торды.

— Сезмени бу? — диде хатын.

— Мин бит сезгә киләм дип вәгъдә иткән идем, менә килдем.

— Сез миңа тагын бернәрсә вәгъдә иткән идегез әле.

— Нәрсә ул? И аллам! — дип сөйләнеп куйды егет, үз-үзен кулда тота белүенә карамастан, аның тез буыннары калтырана башлады, маңгаена тир бәреп чыкты.

— Сез миңа пычак китерергә, без сөйләшеп беткәннән соң аны миңа калдырырга вәгъдә иткән идегез.

— Ул турыда сөйләмәгез, ханым! Алла бәндәсенә никадәр яман булса да, үз-үзенә кул салу хокукы бирерлек хәл юк ул. Мин уйладым да үз өстемә андый гөнаһ алырга һич ярамый дигән нәтиҗәгә килдем.

Әсир хатын, мыскыллы бер төс белән елмаеп, креслога утырганда:

— Ах, сез уйладыгызмыни! — диде.— Мин дә уйладым да бер нәтиҗәгә килдем.

— Нинди нәтиҗәгә?

— Сүзендә тора белмәгән кеше белән сөйләшер сүзем юк дигән нәтиҗәгә.

— Й аллам! — дип пышылдап әйтеп куйды Фельтон.

— Чыгып китсәгез дә була, каршылыгым юк.

— Менә ул пычак! — диде Фельтон, кесәсеннән пычак чыгарып. Вәгъдәсен истә тотып, ул аны бирегә алып килгән, тик әсир хатынга чыгарып бирергә генә кыймый тора иде.

— Бирегез, карыйм әле.

— Нигә?

— Ант әгәр, хәзер үк кайтарып бирәм. Сез аны менә бу өстәл өстенә куегыз да пычак белән минем арага басыгыз.

Фельтон пычакны миледига бирде, миледи игътибар белән аның йөзен карады, бармак очына пычакның очын тидерептидереп алды.

— Яхшы,— дип, пычакны офицер егеткә кире кайтарды,— бик яхшы каты корычтан ясалган икән... Яхшы дус сез, Фельтон.

Фельтон пычакны алгач, килешенгәнгә, өстәл өстенә куйды.

Миледи Фельтонның бу хәрәкәтен күзәтеп торды да, канәгать булып, баш какты.

— Хәзер инде мине тыңлагыз,— диде ул.

Болай дип тыңларга өндәү инде артык: офицер егет аның каршында сөйли башлаганын тәкатьсез көтеп басып тора иде.

Миледи тантаналы бер тавыш һәм сүлпән генә төс белән сүзенә кереште:

— Фельтон,— диде,— әгәр сезнең апагыз, атагызның кызы, сезгә болай дип әйтсә: яшь чагымда, бәхетсезлегемә каршы, бик чибәр чагымда, мине алдап тозакка төшерделәр, тик мин бирешмәдем. Миңа каршы төрле мәкер кора, ирексезли-көчли башладылар, тик мин бирешмәдем. Минем тоткан динемне, инанган алламны мәсхәрә иттеләр, чөнки мин ярдәм сорап аллама һәм шул динемә ялвардым, тик монысында да бирешмәдем. Шуннан инде алар мине хурлый-мыскыл итә башладылар, җанымны үтерә алмагач, тәнемне мәсхәрә итәргә теләделәр. Аннары...

Миледи сүзеннән туктады да ирен читләре белән генә ачынып елмаеп куйды.

— Аннары? Аннары нишләделәр соң? — дип, аның сүзен кабатлап сорады Фельтон.

— Аннары инде, беркөнне кич, болар минем шушы каршылыгымны сындырырга карар кылдылар: шулай итеп, беркөнне кич суга бик көчле йокы даруы кушып бирделәр миңа. Кичке ашны ашап туя белән үк, мин бик гаҗәп рәвештә бөтен гәүдәм хәлсезләнеп оеп барганын тойдым. Бернинди шигем булмаса да, күңелемә нindидер шом-курку төште, үзем йокымнан айнырга, бу хәлгә бирешмәскә тырыштым. Торып, тәрәзәгә барыйм да ярдәмгә кешеләр чакырыйм дип талпынсам, аякларым атламый, түшәм аска иңеп, бөтен авырлыгы белән башымны басып тора кебек. Кулымны сузып, эндәшмәкче-кычкырмакчы булдым, тик авызымнан мыгырдаган бер тавыш кына чыкты. Бөтен гәүдәм берни тоймаслык булып оеп калды, егылып китмәгәем

дип, креслога тотындым, тик озакламый хәлсез кулларым бу терәккә дә тотынып тора алмады, башта бер теземә аудым, аннары — икенчесенә. Дога укымакчы булам — телем әйләнми. Һичшиксез, ходаем мине күрмәгән дә, ишетмәгән дәдер. Мин, үлгән кебек йокыга талып, идәнгә ауганмын.

Шунда йоклагач, ниләр булганын, күпме вакыт дәвам иткәнен берсен дә хәтерләмим. Уянып киткәч, бик зиннәтләп җиһазлаган түгәрәк бер бүлмәдә түшәктә ятканымны гына хәтерлим. Бүлмә эченә түшәмдәге тишектән генә якты төшә. Өстәвенә, аның бер ишеге дә юк шикелле. Моны бик шәп бер зиндан дип уйларлык иде.

Мин шактый вакыт үземнең кая килеп эләккәнемне аңлый алмый яттым, менә хәзер сөйләгән ваклыкларын да аңышмадым: акылым үземне баскан йокы авырлыгын алып ташларга тырышып-тырышып карый да булдыра алмый. Бик томанлы гына булып каретада баруыбыз, бик яман бер төш күреп бастырылуым, шул төшне күргәндә тәмам хәлдән таюым хәтеремдә калган, тик болар бөтенесе минем күз алдымнан, әйлешәйле, өзек-төтек кенә булып узды, әйтерсең бу хәлләрне мин үзем түгел, бәлки икенче бер кеше кичерә кебек, тик җанымның бик гаҗәп рәвештә икегә бүленүе сәбәпле минем тормышыма килеп кушыла, имеш.

Шушы хәлем бер ара миңа бик сәер-гаҗәп тоелып, мин моны төшемдә генә күргәнмен дип уйладым... Чайкала-чайкала торып бастым. Киемнәрем үз янымда урындыкта ята иде, тик мин чишенгәнемне дә, урынга ятканымны да хәтерләмим. Шуннан соң инде бу коточкыч хәлне әкренләп төшенә башладым, үзем яши торган йортта ятмаганлыгымны аңладым. Бүлмәгә төшкән кояш нурларына карап чамалаганда, кояш инде баеп бара иде, ә мин узган көнне кич йокыга талган идем,— димәк, мин бер тәүлек чамасы йоклаганмын! Шулкадәр озак йоклаган арада ниләр булды икән?

Хәлемнән килгәнчә, тиз-тиз генә киенеп алдым. Әкрен генә, хәлсез генә хәрәкәтләнүем йокы даруының әле һаман көче бетмәгәнлеген әйтеп тора иде. Җиһазына караганда, әлеге бүлмә хатын-кызларны кабул итәр өчен эшләнгән иде, күрәсең,— иң талымлы мут хатын да, берәр теләген белдерсә, бүлмә эченә күз йөртеп чыгу белән, теләге үтәлгән икәнен күрер иде.

Һичшиксез, мин бу зиннәтле зинданга бикләнгән әсир хатыннарның беренчесе генә булмаганмындыр, ләкин аңлыйсызмы шуны, Фельтон, шул зинданның матурлыгы күземә күбрәк күренгән саен, йөрәгемә курку төшә барды. Әйе, чын зиндан иде ул, чөнки минем аннан чыгып котылырга маташуым файдасыз булды. Мин ишек эзләп бөтен стеналарны карап чыктым, тик бөтен стенадан, шакып карагач, тыкылдаган тавыш кына ишетелде.

Чыгар юл эзләп бүлмәне бер егерме тапкыр әйләнгәнмендер — бернинди ишек сыман нәрсә тапмадым. Куркуымнан һәм хәлсезлектән аягымда басып тора алмыйча креслога аудым.

Ул арада инде төн җитеп караңгыланып та килә иде. Караңгы куерган саен куркуым тагы да көчәя башлады. Мин утырган җиремдә калырга да, калмаска да белмәдем: бөтен яктан нindидер бер дәһшәт качып-посып мине сагалап торадыр, аз гына кузгалсам да, өстемә ташланыр кебек тоелды. Кичәдән бирле бер ризык капканым булмаса да, куркудан ачыкканымны да тоймадым.

Тыштан кайсы вакыт икәнен белгертерлек бер генә тавыш та ишетелми. Мин чама белән кичке сәгать җиде-сигезләр тирәседер дип кенә уйладым: бу хәл октябрь аенда булган иде, тышта инде караңгы төшеп килә иде

Шунда кинәт ишек шыгырдап куюга, дерт итеп сискәнеп киттем. Түшәмнең пыяла белән капланган тишегендә утлы шар шикелле лампа кабынып китеп, бөтен бүлмә эчен яктыртып җибәрде, шул чагында үземнән берничә адымда гына бер кеше басып торганлыгын күреп котым алынды.

Бүлмә уртасында, сихер белән эшләнгән шикелле, ике кешелек табын әзерләнгән өстәл пәйда булды.

Бу — мине бер ел буе эзәрлекләгән бер кеше иде, ул мине мәсхәрә итәм дип ант иткән иде. Мин аның беренче сүзеннән үк узган төнне үзенең ниятенә ирешкән икәнлеген төшендем.

— Кабахәт! — дип пышылдап әйтеп куйды Фельтон.

Офицер егетнең бу сәер хикәятне йотылып тыңлап торганын күреп, миледи:

— Кабахәтнең кабахәте! — дип кычкырып әйтеп куйды.— Кабахәтнең дә кабахәте! Ул мине йоклаган чагымда җиңсәм, шуның белән хәл ителә дип уйлаган. Хәзер инде мине мәсхәрә иткәч, мине бу хәл белән килешер дип өмет итеп килгән иде ул. Минем мәхәббәтемә алмашка үзенең байлыгын тәкъдим итәргә килгән иде.

Мин хатын-кыз йөрәгенә сыярдай бөтен ачуымны, бөтен нәфрәтемне бу адәмнең битенә бәреп әйттем. Мондый гына шелтәләргә ул күнеккән, күрәсең: кулларын кушырып, елмаяелмая, сабыр гына тыңлап торды; аннары, мине сүзен әйтеп бетерде бу дип уйлап, якын килә башлады. Мин тиз генә өстәлгә барып пычакны алдым да күкрәгемә терәдем.

«Тагын бер генә адым атласагыз да, минем мәсхәрә ителүем өчен генә түгел, үлемем өчен дә вөҗдан газабы кичерергә туры киләчәк сезгә!» — дидем.

Минем күз карашым, тавышым, бөтен гәүдә торышым иң бозык кешеләрне дә ышандырырлык чын бер ихласлык белгертеп тора иде, күрәсең, шул сәбәпле ул туктый калды.

«Сезнең үлемегез өченме? — дип кайтарып сорады.— Ай, юк! Сезне бер генә тапкыр татып әрәм итәргә сез бик гүзәл сөяркә шул,— ди.— Сау булып торыгыз, чибәрем! Мин бераз сабыр итәрмен, кәефегез яхшыра төшкәч килермен»,— ди.

Шулай дигәч, сызгырып җибәрде. Бүлмә эчен яктыртып торган утлы шар түшәмнән өскәрәк күтәрелде дә юкка чыкты. Мин тагын караңгыда калдым. Беравыктан тагын шыгырдап

ишек ачылып-ябылганы ишетелде, утлы шар яңадан аска төште, һәм мин тагын бер ялгызым торып калдым.

Йөрәк яргыч бер минут иде бу. Моңарчы мин бәхетсезлеккә элэгүемә ышанып җитмәгән булсам, хәзер инде андый шигем калмады, мин үземнең коточкыч бер хәлгә төшүемне аңладым: мин яратмаган гына түгел, бәлки дошман күргән кешем кулына, теләсә нинди яманлык эшли ала торган, нәрсә эшли алганлыгын инде миңа күрсәткән бер кеше кулына килеп эләккәнмен.

— Кем иде соң ул кеше? — дип сорады Фельтон.

— Төнне мин, шылт иткән тавышка да сискәнә-сискәнә, урындыкта утырып чыктым, чөнки төн уртасы җитәрәк лампа сүнеп, мин тагын дөм-караңгыда калдым. Шулай да бу төнне мине эзәрлекләгән бәндә андый-мондый этлек күрсәтмәде. Иртән, яктыргач, өстәл юкка чыкты, тик мин һаман пычакны кулыма кысып тоткан килеш утыра бирдем.

Минем бердәнбер өметем шушы пычак кына иде.

Минем инде тамчы да хәлем калмаган, йокламаганнан күзләрем ут кебек кызыша иде, үзем бер генә минутка да йоклап китүдән курыктым. Көн яктысында бераз тынычлана төшеп, караватка барып аудым, бердәнбер өметем булган әлеге пычакны кулымнан ычкындырмадым, мендәр астына яшердем.

Мин уянганда, тагын табын әзерләп өстәл китергәннәр иде.

Бу юлы инде, никадәр курку, кайгы-хәсрәт кичерүемә дә карамастан, бик каты карыным ачканлыгын тойдым: ике тәүлек инде авызыма бер ризык капканым юк иде. Мин бераз ипи, берничә җимеш ашадым. Аннары эчкән суыма йокы даруы кушуларын исемә төшереп, өстәлдәге суга кагылмадым, стенага юынгыч өстенә ясалган мәрмәр фонтаннан стаканыма су агызып алдым.

Шулай саклануыма да карамастан, баштарак бик яман борчылган идем, тик бу юлы куркуым бушка булды: көн үтеп, кич җитте, мин әлеге үземне куркыткан әйбергә охшашлы нәрсә тоймадым. Шикләнүемне сизмәсеннәр өчен графиндагы суның яртысын түгеп куйган идем.

Кич җитте, караңгы төште. Ләкин минем күз инде караңгыга ияләшә башлады, караңгыда өстәлнең аска төшеп китеп, чирек сәгатьтән соң миңа дигән кичке аш белән кире күтәрелгәнен күреп калдым, беравыктан инде теге лампа кабынып, бүлмә эчен яктыртып җибәрде.

Мин, йокы даруы кушып булмастай ризыклардан башка, берсен дә ашамаска булдым. Бөтен ашаганым ике күкәй белән берничә җимеш кенә булды. Аннары инде мәрхәмәтле фонтанымнан су агызып эчтем.

Эчә башлаган чакта ук су иртәнге шикелле тәмле тоелмады. Шундук күңелемә шик төште дә суны эчмәс булдым, шулай да ярты стакан чамасы эчеп өлгергән идем инде.

Җирәнеп, калган суны түктем дә, салкын тиргә төшеп,ниләр булырын көтә башладым.

һичшиксез, качып-посып торган берәр кеше фонтаннан минем су алганымны күреп калган да, беркатлылыгымнан файдаланып, мине ансат кына харап итмәкче булган.

Ярты сәгать чамасы да узмагандыр, беренче тапкыр йокы даруы эчкәндәге галәмәтләр тагы сизелә башлады. Бу юлы инде, ярты гына стакан эчкәнлектән, мин моңа озаграк бирешми тордым, йокыга да талмадым, ничектер йокымсырый гына башладым, үземне үзем сакларлык яисә качарлык хәлем калмаса да, үз тирәмдә ниләр барын сизмәслек-аңышмаслык хәлгә төшмәдем.

Чайкала-чайкала булса да караватка барып җитеп, бердәнбер саклаңыр коралым булган пычакны мендәр астыннан алмакчы булдым, тик мендәргә хәтле барып җитә алмадым, идәнгә тезләнеп, калтыранган кулларым белән карават аягына ябыштым. Шунда инде «бетүем икән» дип уйладым...

Фельтонның йөзе агарынып китте, бөтен тәне чирап-калтыранып куйды.

— Иң яманы шул,— диде миледи, әлеге хәтәр минуттагы шомлы куркынычны кичергән сыман тавыш белән,— бу юлы инде мин үземә куркыныч киләсен ап-аек сиздем: әйткәнемчә, тәнем йокласа да, җаным уяу иде, шуңа күрә мин барысын да күреп-ишетеп тордым. Дөрес, бөтенесен дә төштә күргәндәгечә генә тойдым, шул сәбәпле тагы да яманрак кебек иде.

Мин лампаның өскә күтәрелеп киткәнен, үземнең әкренләп караңгыга чумганымны күреп тордым. Аннары ишек шыгырдаганны да ишеттем, ул ишек нибары ике генә тапкыр ачылган булса да, аның шыгырдавы бик яхшы таныш иде инде миңа.

Шунда мин тәнем белән кемнеңдер үземә таба якынлашканын тоеп алдым, Американың ялан далаларында адашып калган бичара кеше шул рәвешчә үзенә елан якынлашканын тоя, имеш, диләр.

Авызымны ачып кычкырмакчы булдым, җан ачысы белән тырмашып хәтта аягыма да бастым, тик атлый алмадым, шундук яңадан егылдым... үземне эзәрлекләгән кешенең кочагына егылдым.

— Әйтегез әле: кем иде соң ул кеше? — дип кычкырып сорады офицер егет.

Миледи шушылай тәфсилләп сөйләве белән Фельтонның йөрәк-бәгырен телгәләвен бер карауда ук сизде, ләкин аны бу кичереш газабыннан коткарырга теләмәде. Ул аның бәгырен никадәр тирәнрәк телгәләсә, Фельтонның аның өчен үч алырына ышаныч арта гына барачак иде. Шуңа күрә миледи, аның эндәшүен ишетмәгән кебек, аңысын әйтергә вакыт җитмәгән әле дигәндәй, сөйләвендә дәвам итте:

— Тик бу юлы инде ул кабахәт адәм мәет кебек берни тоймас, берни кылмас бичара кыз белән эш итә алмады. Мин сезгә әйткән идем инде: тән һәм җан сәләтем үземә буйсынмаса да, үземә куркыныч киләсен сизеп-тоеп тора идем: мин

бөтен көчемне туплап бирешмәскә тырышканмын, бик нык каршы торганмын, күрәсең, чөнки аның:

«Ах, бу җүнсез пуританкалар! Мин аларның үз палачларын иза чиктерүләрен белсәм дә, сөйгән егетләренә шул хәтле каты каршылык күрсәтәләр дип уйламаган идем», дигәнен ишеттем.

Әмма җан тырмашып көрәшсәм дә, артык каршы тора алмадым шул, хәлем китте, көчем бетте, бу юлы инде әлеге кабахәт адәм минем йокыга китүемнән түгел, һуштан язуымнан гына файдаланды.

Фельтон, бер сүз эндәшмәстән, ыһ-ыһ дип сыкрангалап кына тыңлый бирде.

— Аңыма килгәч, беренче эшем мендәр астындагы бая ала алмаган пычакка омтылуым булды: бая ул миңа сакланырга ярдәм итмәсә, хәзер, һич югы, гаебемне йоларга ярдәм итәр, дидем. Әмма пычакны кулыма алгач, башыма коточкыч бер уй килде, Фельтон. Мин сезгә барысын да әйтеп сөйләргә ант иттем, шулай булгач, барысын да әйтәм. Мин сезгә дөреслекне ачармын дип сүз бирдем һәм, моның белән хәтта үземне харап итсәм дә, мин аны ачамын сезгә.

— Сезнең башыгызга шул кешедән үзегез өчен үч алу уе килдеме? — дип кычкырып сорады Фельтон.

— Әйе шул! — диде миледи.— Христиан кешесенә күңеленә андый уй китерү гөнаһ. Һичшиксез, ул уйны безнең рухыбызның мәңгелек дошманы, безнең тирәдә туктаусыз үкереп торган теге арслан минем күңелемә салгандыр. Кыскасы, дөресен әйтим, Фельтон,— диде миледи, үз-үзен җинаятьчелектә гаепләгән хатын-кыз тоны белән,— күңелемә шул уй керде дә утырды. Әнә шул гөнаһлы уемның менә хәзер җәзасын күрәм инде.

— Сөйләгез, сөйләгез, сезнең ничек үч алганлыгыгызны минем бик беләсем килә,— диде Фельтон.

— Мин мөмкин хәтле тизрәк үч алырга ниятләдем, аның алдагы төнне киләчәгенә ышанып тора идем. Көндез минем өчен куркырлык нәрсә юк иде.

Шуңа күрә, иртәнге аш вакыты җиткәч, берни уйламыйча ашадым, эчтем; кичен исә ашаган булып күренергә, ә үзем бер нәрсәгә дә кагылмаска ниятләдем, шуңа күрә кич карыным ачмасын өчен, иртән ныгытып ашап куярга кирәк иде.

Мин иртәнгедән бер стакан су гына яшереп куйдым, чөнки ике тәүлек буе ашамаган-эчмәгән чагымда бик яман сусаудан газапландым.

Көн буе уйлансам да, шул карарым ныгый гына төште. Үземне күзәтеп торуларына шикләнмәстән, күңелемдәге уемны чыраема чыгармаска тырыштым, хәтта берничә тапкыр үземнең елмаюымны да искәрдем. Фельтон, нәрсә уйлап елмайганымны мин сезгә әйтә алмыйм, әйтсәм, сезнең миннән гайрәтегез чигәр иде...

— Сөйләгез, сөйләгез,— диде Фельтон үтенгән тавыш белән,— күреп торасыз бит: мин тыңлыйм, азагы ничек булып беткәнен тизрәк беләсем килә.

— Кич житте, бөтенесе көндәге тәртип белән дәвам итә. Гадәттәгечә, караңгыда миңа кечке ашны менгезделәр, аннары лампа кабынды һәм мин өстәл янына барып утырдым.

Нибары берничә җимеш кенә ашадым мин, графиннан су салып алган булып кыландым, ләкин үзем иртәнгедән алып калган суны гына эчтем. Хәер, мин аны шундый оста алмаштырдым, шымчыларым булып, карап торсалар, алар да берни сизмәсләр иде.

Кичке ашны ашаганнан соң, мин кичәге шикелле үк үземне йокы басканга салыштым, тик бу юлы инде бик арган-хәлдән тайган гына яисә курыкмый башлаган булып кына караватка чаклы барып җиттем дә күлмәгемне салып ташлап, йокларга яттым.

Мендәр астыннан кулым белән эзләп пычакны таптым да, йоклаганга салышып, кулыма чытырдатып кысып тоттым.

Ике сәгатьләп вакыт узды, ул-бу булмады, и аллам, кичә булса үзем дә ышанмас идем — мин аны килми ахры дип курка ук башладым!

Ниһаять, лампаның әкрен генә күтәрелеп, түшәмнән бик өстә юкка чыкканын күреп калдым. Бүлмә эче дөм-караңгы булды, шулай да, текәлебрәк карагач, караңгыда беркадәр шәйли башладым.

Ун минутлап вакыт узды. Шылт иткән тавыш та юк, дөп-дөп итеп йөрәгем типкәне генә ишетелә.

Әлеге адәм тизрәк килсен иде дип ходайга ялвара башладым.

Ниһаять, теге бик таныш тавыш — шыгырдап ишек ачылып-ябылганы һәм берәүнең калын келәм җәелгән идәнне шыгыр-шыгыр китереп атлаганы ишетелде. Караңгыда караватыма таба килгән ниндидер кеше шәүләсен күреп алдым.

— Тизрәк сөйләгез, тизрәк! — дип ашыктырды Фельтон.— Һәр сүзегез йөрәгемне эрегән кургаш төсле көйдереп алганын күрмисезмени?

— Шунда инде бар булган көчемне җыйдым,— дип сөйләвендә дәвам итте миледи,— үч алыр вакыт җитте, дөресрәге — гадел хөкем үз сүзен әйтер вакыт җитте дип тәкрарладым, үз-үземне яңа бер Юдифь итеп күрдем. Тәвәккәлләдем дә пычакны кулыма чытырдатып кысып тоттым, әлеге адәм яныма килеп, караңгыда корбанын эзләп кулын суза башлагач, җан ачысы белән чырылдап җибәрдем дә күкрәгенә пычак белән китереп кададым.

Җүнсез, бөтенесен алдан уйлап, чарасын күреп куйган: күкрәгенә көбә киеп алган булган, пычагым шуңа гына кадалды. «Әһә! — дип кычкырып җибәрде бу, кулымны эләктереп, пычакны каерып алды,— сез мине үтермәкче буласызмы әле, гүзәл пуританка! — ди.— Бу инде нәфрәт кенә түгел, чын мәгънәсендә яхшылыкның кадерен белмәү! — ди.— Ярый, ярый, тынычланыгыз, матурым! Мин сезнең инде ачуыгыз беткәндер дип уйлаган идем,— ди.— Мин хатын-кызны көчләп тотучы залимнардан түгел, мин, үз-үземә артык ышанып, мине яратасыз-

дыр дип уйлаган идем — сез мине яратмыйсыз икән. Хәзер инде мин моңа тәгаен ышандым, иртәгә азат булырсыз»,— ди.

Шунда мин аның фәкать үземне үтерүен генә теләдем.

«Сак була күрегез, минем иреккә чыгуым сезгә хурлык китерәчәк»,— дидем мин аңа.

«Аңлатыбрак әйтегез әле, чибәр сивиллам» *,— ди.

«Яхшы,— мин әйтәм.— Мин моннан котылу белән барысын да кешеләргә сөйләп бирәм, мине көчләвегезне дә, әсирлектә тотуыгызны да әйтәм. Җыен кабахәтлек эшләп ята торган шушы сараегыз барлыгын бөтен кешегә таратам. Милорд, дәрәҗәгез бик зур булса да, сезне куркытучылар да бар — сездән югарырак король бар, корольдән дә югарырак алла бар!» — дидем.

Мине эзәрлекләүче бәндә үзен-үзе кулда тота белсә дә, ачулы бер хәрәкәтеннән тыелып кала алмады. Мин аның чыраен күрмәсәм дә, минем кулымны тоткан кулы калтыранып киткәнен тойдым.

«Ул чагында сез моннан чыкмаячаксыз!» — диде бу.

«Бик яхшы! — мин әйтәм.— Минем газап күргән урыным каберем булыр. Бик шәп! Мин шушында үлеп калырмын, шуннан соң инде минем өрәгемнең тере кешенең куркытуыннан яманрак икәнлеген күрерсез»,— дидем.

«Сезгә бернинди корал калдырмаячаклар»,— ди бу.

«Өметсезлек дигән нәрсә йөрәге булган һәр җан иясенә бер корал биргән — мин шуны кулланачакмын. Ачтан үләчәкмен»,— дидем.

«Карагыз әле, мондый ызгыштан татулык яхшырак булмасмы? — ди бу әшәке бәндә.— Мин сезне хәзер үк иреккә чыгарам, сезне иң яхшы кеше дип, Англиянең Лукрециясе итеп игълан итәм»,— ди.

«Ә мин сезне аның Сексты дип игълан итәм, сезне ходай алдында фаш иткән кебек, бөтен кеше алдында йөзегезне ачам, Лукреция кебек, гаепләвемне каным белән беркетергә кирәк булса, анысын да эшләрмен»,— дидем.

«Әһә! Ул чагында эш башка,— диде дошманым көлеп.— Валлаһи, аңа китсә, сез монда бик яхшы яшисез, бернинди мохтаҗлык күрмисез, ачтан үләсез икән, үзегез генә гаепле булачаксыз»,— ди.

Шулай дип бу китеп барды. Ишек ачылып ябылганы ишетелде. Ихластыр, шунда мин, кайгы-хәсрәтемнән бигрәк, үчемне кайтара алмавым хурлыгыннан түнеп калдым.

Сүзендә торды ул. Көн узды, төн узды, күренмәде бу. Мин дә сүземдә тордым, берни ашамадым, эчмәдем. Аның алдында әйткәнчә, мин ачтан үләргә карар иттем.

Көнем белән төнемне гыйбадәт кылып уздырдым: ходаем минем мордар китүемне кичерер дип өметләндем.

---

* Сивиллалар — борынгы грек легендаларындагы күрәзәче хатыннар.

Икенче төнне тагын ишек ачылды. Мин инде хәлем бетеп идәндә ята идем.

Ишек шыгырдаганны ишеткәч, кулыма таянып бераз күтәрелә төштем.

Колагыма дәһшәтле булып таныш тавыш ишетелде:

— Я, ничек, бераз йомшардыгызмы инде? — дип сорады бу.— Бары тик беркемгә сөйләмәм дип сүз бирү хакына гына ирек алырга ризамы сез? — ди.— Карагыз әле, мин яхшы кеше,— ди,— пуританнарны яратмасам да, хөрмәт итәм, шулай ук, пуританкаларны да — сөйкемле-чибәрләрен,— ди.— Я, тәре тотып ант итегез инде, шуннан башка нәрсә сорамыйм мин сездән»,— ди.

— Сезнең каршыда тәре тотып ант итәмме?! — дип кычкырып җибәрдем мин, яткан җиремнән тора башлап; шул дошман адәмнең тавышын ишеткәч, яңадан көч-хәл керең китте миңа.— Тәре тотыпмы?! Ант итеп әйтәм: бернинди вәгъдә дә, бернинди куркыту-янау да, бернинди җәза-газап та минем авызымны йомдыра алмас!.. Тәре тотыпмы?! Ант итеп әйтәм: мин сезне бөтен җирдә кеше үтерүче, кешенең намусын пычратучы әшәке бер җан дип фаш итеп йөриячәкмен!.. Тәре тотыпмы?! Ант итеп әйтәм: берәр вакыт моннан котылсам, мин бөтен адәм ыруына сездән үч алырга дип ялварачакмын!» — дидем.

Ул моңарчы булмаган дәһшәтле-усал бер тавыш белән әйтте шунда:

«Сак булыгыз! Сезнең авызыгызны йомдыра торган, яки һич югы, кешеләрне сезнең бер сүзегезгә дә ышанмаслык итә торган бик ышанычлы чарам бар — ул чараны иң ахыр чиктә генә кулланам мин»,— диде.

Мин, аның шулай куркытуына каршы, соңгы көчемне җыеп, шаркылдап көлеп җибәрдем.

Моннан ары безнең арада мәңгелек кан дошманлыгы гына булачагын аңлады бугай ул.

«Карагыз әле, мин сезгә уйланырга бераз вакыт бирәм: менә бүгенге бу төннең калган кадәресе һәм иртәгәсе көн бар. Әгәр сөйләмәскә сүз бирсәгез, үзегезне байлык-муллык, кадер-хөрмәт, хәтта дан-шөһрәт көтә, әгәр инде мине куркытырга уйласагыз, мин сезне хурлыкка төшерәчәкмен»,— ди бу.

«Сезме?! Сезме?!» — дип кычкырып җибәрдем мин.

«Гомерлеккә җуелмаслык хурлык!» — ди.

«Сезме?!» — дип кабат кычкырдым. Ай, ихластыр, Фельтон, мин аны акылыннан язгандыр дип уйладым.

«Әйе, мин!» — диде бу.

«Аһ, калдырыгыз мине, күз алдыгызда башымны стенага бәреп яруымны теләмәсәгез, чыгып китегез моннан!» — дидем мин аңа.

«Ярый, яхшы, сез теләгәнчә булсын. Иртәгәге кичкә хәтле»,— диде бу.

Мин дә, идәнгә капланып, ярсуымнан келәмне тешли-тешли: «Иртәгәге кичкә хәтле!» — дидем.

Фельтон инде аның сөйләгәнен креслога таянып тыңлап тора иде. Миледи, егетнең бу хикәятне азагына чаклы тыңлап торырга түземе җитмәслеген күреп, астыртын гына сөенеп куйды.

## XXVII

## КЛАССИК ТРАГЕДИЯНЕҢ СЫНАЛГАН БЕР ЫСУЛЫ

Миледи, егетне астыртын гына күзәтеп, беравык дәшми торганнан соң, тагын сөйләп китте:

— Өч көн буе диярлек берни ашамадым, эчмәдем, бик газаплы-авыр булды миңа: вакыт-вакыт ниндидер болыт маңгаемнан басып, күзләремне каплап-томалап торган кебек тоела — шуннан инде саташа ук башлый идем.

Кич булды. Хәлсезлегем шул дәрәҗәгә җитте — минут саен аңымны җуя башладым һәм һушымнан язган саен, аллага шөкер, үләм икән дип, ходаема рәхмәт укыдым.

Бер тапкыр әнә шулай һушсыз калгач, ишек ачылганны ишеттем; куркуымнан шундук аңыма килдем.

Минем янга ул битлек кигән ниндидер бер кеше ияртеп керде; үзе дә битлек кигән иде, тик мин аны аяк атлавыннан, тавышыннан таныдым, кешелек дөньясына бәхетсезлек итеп җәһәннәм биргән шул мәһабәт кыяфәтеннән таныдым.

«Я, мин сораганча ант итәргә ризамы сез?» — диде ул.

«Пуританнарны әйткән сүзләрендә нык торалар дип үзегез әйттегез бит. Үзегез дә ишеттегез: мин сезне бу дөньяда кешеләр хөкеменә, ә теге дөньяда ходай хөкеменә куйдырырга сүз бирдем»,— дидем мин.

«Димәк, сез һаман киреләнәсез?» — ди бу.

«Үземне ишетеп торган ходай каршында ант итеп әйтәм: бөтен дөньяны сезнең җинаятегезнең шаһиты итәчәкмен, үч алучы кеше тапмыйча, ул эштән туктамаячакмын»,— дидем.

«Сез — фахишә, шуңа күрә андый хатыннарга тиешле җәзаны алачаксыз! — диде ул күкрәп чыккан бер тавыш белән.— Үзегез мөрәҗәгать итәргә җыенган бөтен дөнья күз алдында хурлык тамгасы белән йөри башлагач, үзегезнең җинаятьче һәм исәр түгеллегегезгә шул дөньяны ышандырып карарсыз менә!»

Шулай дигәч, битлек кигән кешегә эндәште.

— Палач, эшеңне эшлә! — дип боерды.

— О! Исеме кем? Исеме?! Исемен әйтегез әле! — дип кычкырып җибәрде Фельтон.

— Шуннан инде, минем кычкыруыма, каршы торуыма карамастан (үземә әҗәлдән дә яманрак нәрсә эшләргә җыенуларын сизенә башлаган идем инде мин), палач мине эләктереп алды да идәнгә егып, куллары белән кысып тотты. Мин үкереп-үкереп еладым, һушларымны җуя яздым, ходаема ялвардым, тик ул минем гозеремне ишетмәде... Аннары инде авыртуга һәм хурлыкка түзә алмыйча чырылдап кычкырып җибәрдем — кызган тимер, палач тимере кулбашымны пешереп алды.

Фельтон дәһшәт салгандай «уһ!» дип кычкырып куйды.

— Менә карагыз,— дип, миледи королеваларча мәһабәт бер кыяфәт белән торып басты,— менә карагыз, Фельтон, залим бәндәнең корбаны булган гөнаһсыз бер яшь кыз өчен нинди яңа җәза уйлап тапканнар. Кешеләрнең йөрәгендә ни барын күрә белергә өйрәнегез һәм моннан ары, уйламый-нитми генә, аларның явызлык коралына әйләнмәгез.

Миледи тиз генә күлмәк изүен ачып җибәрде, түшен каплап торган батистны ертып төшерде дә, ярсуыннан һәм оялуыннан кызарынган булып, егеткә үзенең матур тәненә хурлык билгесе итеп сугылган җуелмас тамганы күрсәтте.

— Лалә чәчкәсе күрәм мин монда! — диде Фельтон шаккатып.

— Бөтен эшәкелеге дә шунда шул! — диде миледи.— Инглиз тамгасы булса икән әле ул! Югыйсә кайсы суд миңа тамга сугарга хөкем чыгарганлыгын исбат итәргә кирәк булыр иде, ә мин дәүләттәге барлык судка шикаять язып биргән булыр идем. Француз тамгасы исә... О, алар өчен бик ышанычлы тамга булды ул!

Фельтонның күңеле бу кадәресен инде күтәрә алырлык түгел иде.

Миледи сөйләгәннәргә шаккатып, оялмый-нитми ялангач тәнен күрсәткән (моны Фельтон үзенә бер җан олылыгы дип аңлады) бу хатынның гайре табигый чибәрлегенә таң калып, агарынган бер төс белән хәрәкәтсез катып торганнан соң, ул аның каршына килеп тез чүкте,— христиан динен эзәрлекләүче императорлар тарафыннан циркта кансыз-бәгырьсез гавамнан мәсхәрә иттерелгән гөнаһсыз изге газап чигүчеләр алдында беренче христианнар да нәкъ шулай тез чүккәннәр. Хурлыклы тамга егетнең күзенә күренмәс булды, бары тик хатынның матурлыгы-гүзәллеге генә торып калды...

— Гафу итегез! Гафу итегез! Берүк кичерегез мине! — диде Фельтон.

Миледи аның карашыннан: «яратам, яратам» дигән мәгънәне аңлады.

— Нәрсәгезне гафу итим? — дип сорады.

— Сезне җәберләүчеләргә кушылган булуым өчен гафу итегез.

Миледи егеткә кулын сузды.

Фельтон аның кулын үбә-үбә:

— Шундый матур, шундый яшь! — дип әйтеп куйды.

Миледи аңа колларны да король итә торган күз карашын бүләк итте.

Фельтон пуритан иде — хатынның кулын ычкындырды да аның аякларын үбәргә кереште.

Ул инде миледины ярату гына түгел, алла урынына күрә иде.

Таң калып соклану мизгеле үтеп, милединың бер минутка да җуймаган тынычлыгы кире кайткан кебек булгач һәм оят пәрдәсе мәхәббәт хәзинәсен яңадан каплап куйгач (хәер, гүзәл

хатын егетне тагын да өмсендерү өчен генә яшерергә тырышкан булды аны), Фельтон әйтте:

— Хәзер инде минем сездән бер генә нәрсә үтенәсем калды: сезнең чын палачыгызның исеме кем? Минемчә, палач бер генә монда, икенчесе — аның кулында корал гына булган.

— Ничек инде, туганым?! — дип кычкырып әйтеп куйды миледи.— Сиңа шуны әйтеп тә биримме инде?! Үзең төшенмәденмени?

— Ничек ул?! — диде Фельтон.— Улмыни?.. Тагын улмы?.. Һаман ул... Ничек инде?! Чын-чыннан гаепле кеше...

— Чын-чыннан гаепле кеше — Англияне бөлдерә, чын дин тотучыларны җәберли, кабахәт рәвештә күпме хатын-кызның намусын таптаган, үзенең кунел бозыклыгы өчен генә күпме инглизнең канын койдыра, бүген протестантларны якласа, иртәгә аларга хыянәт итә...

— Бекингэм ул! Бекингэм бит ул! — дип Фельтон ачу-ярсу белән кычкырып җибәрде.

Миледи, шушы исем белән бәйләнгән хурлыклы хатирәләр күңеленә тигән сыман, куллары белән битен каплады.

— Бекингэм — шушы фәрештә затын газаплаучы палач! — диде Фельтон.— И тәнрем, яшен ташың белән ник бәреп үтермәдең шуны! Ник син аны безнең бәхетсезлеккә бай нәселле, дан-хөрмәтле, көчле-кодрәтле иттең!

— Үз-үзен күрмәгән кешене тәңре дә күрми,— диде миледи.

— Димәк, ул үз башына ил-көннән куылганнар җәзасын алырга тели! Ходай хөкем иткәнче үк кешеләр хөкем итүен тели! — диде Фельтон тагы да әсәрләнә төшеп.

— Кешеләр аннан куркалар, кызганалар аны.

— О! Мин курыкмыйм, кызганмыйм аны! — диде Фельтон бу сүзгә каршы.

Миледи күңеленең астыртын яман бер шатлык белән тулганын тойды.

— Әмма минем химаячем, атам, лорд Винтер ничек бу эшкә килеп катнашкан соң? — дип сорады Фельтон.

— Карагыз әле, Фельтон, дөньяда түбән җанлы, әшәке кешеләр белән бергә олы җанлы, яхшы кешеләр дә бар бит. Минем кияү егетем бар иде, ул кешене мин бик ярата идем, ул да мине ярата иде... Сезнең кебек батыр йөрәкле иде, Фельтон, сезнең шикелле бер кеше иде. Мин аның янына бардым да бөтенесен сөйләп бирдем. Мине белә иде ул, аз гына да икеләнмәде. Бөтен яктан Бекингэмга тиң, атаклы-бай вельможа иде ул. Бер сүз дә әйтмәде, биленә кылычын тагып, плащына төренде дә Бекингэмның сараена китте.

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде Фельтон.— Хәер, андый кешеләр белән эш иткәндә, кылыч түгел — хәнҗәр кирәк.

— Бекингэм шуннан алдагы көнне генә Испаниягә гадәттән тыш илче булып — ул чагында әле принц Уэльсле дип аталган король Карл I гә — инфантаны ярәшергә киткән булган. Минем кияү егетем ниятен башкара алмыйча кайтты. «Карагыз әле,

ул кеше Испаниягә китеп барган, хәзергә мин үч ала алмыйм аннан. Сөйләшенгәнчә, ул кайтканчы никахлашып куйыйк,— ди бу,— аннары инде лорд Винтерга таянырсыз, ул үз абруен да, хатыны абруен да саклый белер»,— ди.

— Лорд Винтерга! — дип кычкырып куйды Фельтон.

— Әйе, лорд Винтерга,— дип җөпләде миледи.— Хәзер инде сезгә барысы да аңлашылгандыр, шулаймы? Бекингэм бер ел чамасы Испаниядә торды. Аның кайтырына бер атна кала лорд Винтер көтмәгәндә үлеп китте, мин аның бердәнбер варисы булып калдым. Бу зур бәхетсезлекне кем китергәндер — аныcын бер ходай гына белә, мин берәүне дә гаепле итәргә җыенмыйм.

— Ай, шулкадәр дә түбән төшәргә мөмкин бит! Шулкадәр дә түбән! — дип ачынды Фельтон.

— Лорд Винтер абыйсына берни әйтми үлеп китте. Бу коточкыч сер, гаепле кешене яшен урынына сукмый торып, беркемгә дә билгеле булырга тиеш түгел. Байлыгы булмаган яшь бер кызга энесенең өйләнүе сезгә яхшылык иткән кешегә ошамады. Мин инде мирас алам дип алданган кешенең ярдәменә исәп тотып булмаслыгын аңладым да Франциягә күчеп киттем, калган гомеремне шунда яшәргә булдым. Ләкин минем бөтен байлыгым Англиядә. Сугыш аркасында ике дәүләт арасында аралашу-йөрешү юк, шуңа күрә, мохтаҗлык күрә башлагач, ирексездән бирегә кайтырга туры килде миңа. Моннан алты көн элек мин Портсмутка килеп төшкән идем.

— Шуннан соң? — дип сорады Фельтон.

— Шуннан соңмы? Бекингэм минем бирегә кайтуымны белгән, күрәсең, аңсыз да миңа каршы булган лорд Винтер белән минем хакта сөйләшкән дә, киленегез — бозык хатын, тәненә хурлык тамгасы сугылган җинаятьче, дигән. Мине яклап бер-бер чара кылырга ирем дөньяда юк шул инде. Лорд Винтер үзенә сөйләгәннәрнең барысына да ышанган, үзе өчен файдалы булгач, ышанмый хәле юк. Калганы сезгә билгеле инде: берсекөнгә ул мине еракка сөрәчәк, сөргенгә җибәрәчәк, берсекөнгә ул мине гомерлеккә куылганнар арасына озата. Һай, ышаныгыз сүземә, бу явызлыкны бик уйлап эшли алар! Җәтмәне бик оста корганнар, мине хурлыкка төшереп харап итәләр! Фельтон, минем үләргә тиешлегемне үзегез дә күреп торасыз бит. Фельтон, бирегез миңа пычакны!

Шулай дигәч, миледи, бүтән көче калмаган кебек, хәлсезләнеп, мәхәббәттән, ачу-ярсудан һәм моңарчы татып карамаган ләззәттән әсәренгән офицер егетнең кочагына ауды; егет аны дәртләнеп кочып алды да күкрәгенә кысты, бу матур авызның сулышыннан йөрәге леп-леп килде, калку түшләренең тәненә тиюеннән акылларын җуя язды.

— Юк, юк! — диде ул.— Юк, син үлмисең, кадер-хөрмәттә, тапсыз-керсез булып яшәрсең, дошманнарыңнан өстен чыгар өчен яшәрсең!

Миледи аны кулы белән әкрен генә читкәрәк этәрде дә егетнең күзенә карады; әмма Фельтон аны янә кочаклап алды, егет-

нең күзләре миледига илаһи бер затка ялварган кебек инәлеп карый иде.

Миледи, тавышына моңсу-сагышлы бер төс биреп һәм күзләрен йомып:

— Ай, үлем! Үлем! — диде.— Ай, мондый хурлыкка төшкәнче үлүем мең өлеш хәерлерәк! Фельтон, туганым, дустым, гозерләп сорыйм синнән.

— Юк! Юк, син үлмисең, яшисең, үчең кайтыр! — диде Фельтон.

— Фельтон, үз тирәмдәге кешеләргә мин бәхетсезлек кенә китерәм! Калдыр мине, Фельтон! Үләргә ирек бир миңа!

— Алай булганда бергә үләбез! — диде Фельтон, тоткын хатынны иреннәреннән үбеп.

Дөп-дөп иттереп ишекне какканнары ишетелде. Бу юлы инде миледи Фельтонны чынлап торып этеп җибәрде.

— Ишетәсеңме?! Безне ишеттеләр, монда киләләр! Беттек, харап булдык! — диде ул.

— Юк, сакчы шакылдата, дозор килә дип, мина искәртә,— диде Фельтон бу сүзгә каршы.

— Алайса тизрәк ишеккә йөгерегез дә ишекне үзегез ачыгыз.

Фельтон ул кушканча эшләде — бу хатын инде аның бөтен уй-тойгыларын, бөтен күңелен үзенә буйсындырып өлгергән иде.

Фельтон ишекне ачып җибәрүгә, сакчы патрульгә командалык итүче сержант белән йөзгә-йөз туры килде.

— Нәрсә бар? — дип сорады лейтенант егет.

— Ярдәмгә чакырганыгызны ишетсәм, ишекне ачарга кушкан идегез бит, тик сез мина ачкычны калдырырга оныткансыз,— диде солдат.— Мин сезнең сүзләрегезне төшенмәсәм дә, кычкырганыгызны ишеттем, ишекне ачмакчы идем дә, эчтән бикләнгән булып чыкты. Шуннан инде сержантны чакырдым.

— Сезнең карамагыгызга килдем,— диде сержант.

Фельтон, бер сүз әйтә алмыйча, аптырап-исәнгерәп, тик басып тора бирде.

Шунда миледи боларның игътибарын үзенә җәлеп итәргә кирәклеген төшенеп алды, өстәл янына йөгереп барып, шунда Фельтон куйган пычакны алды да:

— Ә сезнең мина үләргә комачауларга ни хакыгыз бар? — дип кычкырды.

Фельтон, аның кулында пычак ялтырап киткәнен күреп:

— Йа алла! — дип куйды.

Шул минутта коридорда кемнендер хихылдап көлгәне ишетелде.

Тавышка игътибар итеп, ишектә барон күренде — ул өстенә халат кигән, култык астына кылычын кыстырган иде.

— Ә-ә! — диде барон.— Менә көткән трагедиябезнең соңгы пәрдәсе дә җитте! Күрдегезме, Фельтон, нәкъ мин әйткәнчә, драма бер-бер артлы бөтен фазасын узды. Бер дә борчылмагыз, кан коелмас.

Миледи, менә хәзер үк Фельтон күз алдында бик хәтәр кы-

ланып үзенең йөрәкле икәнлеген күрсәтмәсә, тәмам бетәчәген төшенеп алды.

— Ялгышасыз, милорд, кан коелачак, шул кан аны коярга мәҗбүр иткән бәндәләргә каргыш булып төшсен!

Фельтон «аһ!» дип куйды да миледига таба ташланды, ләкин өлгерми калды — миледи үз-үзенә пычак белән китереп кадады.

Тик, бәхеткә каршы, дөресрәге — милединың оста кулы аркасында, пычакның очы ул заманда, калкан кебек, хатын-кызның күкрәген саклаган корсет тимеренә туры килде. Пычак таеп китте дә, күлмәкне ертып, кыйгачлап тире белән кабырга арасына керде.

Шулай да милединың күлмәгенә кан тибеп чыкты.

Хатын, һушыннан язган кебек, идәнгә чалкан авып төште.

Фельтон пычакны тартып алды.

— Күрегез, милорд, минем сактагы хатын бу, үз-үзенә кул салды,— диде ул караңгы бер чырай белән.

— Бер дә борчылмагыз, Фельтон, бу хатын исән, үлмәде,— диде лорд Винтер аның сүзенә каршы,— явыз рухлар алай тиз генә үлми алар; борчылмагыз, барыгыз, минем бүлмәгә кайтыгыз, мине шунда көтеп торыгыз.

— Әмма, милорд...

— Боерып әйтәм, барыгыз, китегез.

Фельтон, башлыгының кушканына буйсынып, китә башлады, бүлмәдән чыккан чагында пычакны куенына яшерде.

Лорд Винтерга килгәндә исә, ул миледига хезмәт күрсәтүче теге хатынны чакыртты, хатын килгәч, аңа һаман да һушсыз яткан тоткын хатынны карарга кушты да икесен генә калдырып чыгып китте.

Шулай да, милединың ярасы шактый җитди булганлыктан, шундук врач чакырырга атчабар җибәрде.

## XXVIII

## КАЧУ

Лорд Винтер уйлаганча, милединың ярасы ул кадәр куркыныч түгел иде; үзен ашыга-ашыга чишендерә башлаган әлеге хатын белән икәү генә калгач, миледи күзен ачты.

Шулай да аңа хәлсезләнгән, авыру булып күренергә кирәк иде, миледи кебек комедиантка өчен исә анысы инде әллә ни кыен эш түгел иде; хезмәтче хатын, бичара, милединың хәйләсенә алданып, ахмак бер сантый булып калды, һәм, тоткын хатынның теләмәвенә дә карамастан, төн буе аның караваты янында утырып чыгасы итте.

Ләкин янында бу хатын булуы миледига үз уйларын уйларга бер дә комачауламады.

Һичшиксез, Фельтон миледи сөйләгәннәрнең дөреслегенә ышанды. Фельтон аңа бөтен күңеле белән ирелде; әгәр хәзер аның каршына изге фәрештә килеп, миледины гаепли башласа,

бу хис халәтендә Фельтон шул фәрештәне иблис иярчене дип кенә белер иде.

Шуларны уйлагач, миледи елмаеп куйды, чөнки моннан ары аның бердәнбер өмете, бердәнбер котылыр чарасы бары тик Фельтон гына иде.

Әмма лорд Винтерның хәзер аннан шикләнүе, Фельтонның үзен дә күзәтә башлаулары ихтимал бит.

Иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә врач килеп житте, ләкин милединың ярасы инде йомылган иде, шуңа күрә врач ул яраның кая таба кергәнлеген дә, тирәнлеген дә тикшереп тормады, фәкать авыруның кан тибешен капшап карап, хәле куркырлык түгел икәнлеген генә белде.

Иртән инде миледи, төне буе йоклый алмадым, миңа бераз ял кирәк дигән булып, үзен караган хатынны кайтарып җибәрде.

Аш китергән чакларында ул Фельтон да килер дип өметләнеп торган иде, әмма Фельтон күренмәде.

Әллә әлеге шигенең раска чыгуы микән бу? Барон шикләнә башлаганнан соң, иң хәлиткеч минутта Фельтон килми калыр микәнни? Милединың тагын бер генә көне калды: лорд Винтер аңа, кораб егерме дүрте көнне китәчәк, диде, ә менә бүген егерме икесенең иртәсе житте инде.

Шулай да миледи, сабырлык саклап, төшкә чаклы көтте.

Иртән ул берни ашамаган булса да, төшке ашны вакытында китерделәр, шул чагында миледи үзен саклаучы солдатларның киеме башка төрле булуын искәртеп, куркуга төште. Шуннан соң ул, батырчылык итеп: «Фельтон кайда?» — дип сорады. Фельтон моннан бер сәгать элек атка атланып каядыр китеп барды, диделәр аңа.

«Барон һаман замоктамы әле?» — дип тә сорады. Солдат «әйе» диде, әгәр тоткын хатынның барон белән сөйләшергә теләге булса, бу турыда үзенә җиткерергә кушты, дип тә өстәде.

«Хәзергә әле сөйләшерлек хәлем юк, бердәнбер теләгем — ялгыз калу», — дип җавап бирде миледи.

Солдат ашны өстәлгә куйды да чыгып китте.

Фельтонны сактан алганнар, диңгез пехотасы солдатларын алмаштырганнар — димәк, моннан ары Фельтонга ышанмыйлар инде!

Тоткын хатынның соңгы тапкыр тез астына сугу иде бу.

Бүлмәсендә ялгызы калгач, миледи торып басты: ярасы авыр икән дип белсеннәр өчен ул иртәдән бирле түшәгендә яткан иде, — менә хәзер шул түшәге, яккан тимер мич кебек, бөтен тәнен кыздыра иде. Миледи ишеккә күз салды: ишектәге кечкенә тәрәзәгә такта кадаклаганнар иде. Шул тишек аша миледи берәр төрле иблис ысулы кулланып сакчыны алдамагае дип курыккандыр, күрәсең, барон.

Сөенеченнән миледи елмаеп куйды: менә хәзер инде ул, ичмасам, ни эшләгәнемне күзәтеп торалар дип курыкмыйча, күне-

лендә кайнаган кичерешләренә ирек бирәчәк. Читлеккә ябылган юлбарыс шикелле, ул ярсуыннан бүлмә эчендә арлы-бирле йөренә башлады. Мөгаен, теге пычак монда калган булса, бу юлы ул үз-үзен түгел, бәлки баронны үтерергә маташып карар иде.

Сәгать алтыда лорд Винтер килде: бу юлы баштан-аяк коралллы иде ул. Моңарчы милединың король сараендагы акылга сайрак бер кавалер дип уйлаган кешесе бер дигән төрмәче булып чыкты: ул барысын да алдан белеп-сизеп тора, чарасын күреп куя икән.

Барон миледига бер күз салу белән үк хатынның күңелендәниләр барлыгын төшенеп алды.

— Ярый, шулай булсын, тик сез мине бүген үтерә алмыйсыз әле,— диде ул,— сезнең хәзер коралыгыз юк, аннары мин дә бик уяу. Сез бичара Фельтонның башын-күзен әйләндерә башлагансыз, ул инде сезнең шайтан вәсвәсәсенә бирелә дә башлаган, тик мин аны коткарып калырга телим, моннан соң ул сезне бүтән күрмәячәк, шуның белән тәмам. Әйберләрегезне җыя башлагыз — иртәгә юлга чыгасыз. Башта мин сезнең китү көнегезне егерме дүртенә дип билгеләгән идем дә, аннары тизрәк озатсам, яхшырак булыр дигән фикергә килдем. Иртәгә төшкә сезне сөргенгә сәрү турында Бекингэм имза салган боерык минем кулда булачак. Әгәр сез корабка утырганчы берәр кеше белән бер генә сүз сөйләшсәгез дә, минем сержант маңгаегызга пуля җибәрәчәк,— аңа шундый боерык бирелгән. Корабта капитан рөхсәтеннән башка берәр кеше белән бер генә сүз сөйләшсәгез дә, капитан сезне диңгезгә ташлатачак — шундый боерык бирелгән аңа. Сау булып торыгыз, бүген минем сезгә әйтәсе сүзем шул гына иде. Иртәгә мин сезне күрермен әле, саубуллашырга килермен!

Шулай дип, барон чыгып китте.

Миледи бу дәһшәтле нотыкны тыштан бер дә исе китмәгән шикелле, авыз чите белән генә елмаеп, эченнән исә зәһәр ачу белән тыңлап торды.

Кичке ашны китерделәр. Миледи әйбәтләп ашап куярга кирәк дигән уйга килде: алдагы төнне ниләр буласын белеп булмый; караңгы, җилле-давыллы төн якынлашып та килә инде; күктә актарылып кара болытлар агыла, ә еракта ялт-йолт иткән яшен яктысы күк күкрәп яңгыр явасын белгертеп тора иде.

Төнге сәгать уннар тирәсендә күкрәп-яшьнәп яңгыр ява башлады. Җанындагы кара давылны әнә шулай табигать тә уртаклашуын күреп, милединың күңеле сөенечтән җилкенеп-җилкенеп куйды; аның йөрәгендәге ачу-ярсу шикелле, күктә дә дөбер-шатыр килеп күк күкри иде; давыл җилләре, агач ботакларын иеп-иеп, яфракларын йолкып-йолкып очырткан кебек, аның да битләренә ургылып-ургылып бәрелә сыман тоела; ул да давыл шикелле улый, һәм аның тавышы уһ-уһ итеп ярсыган-дулаган табигатьнең куәтле авазына кушылып китә иде.

Шул чагында миледи кинәт тәрәзә шакыганны ишетте һәм тонык кына ялтырап киткән яшен яктысында тимер рәшәткәнең теге ягында бер кеше чыраен күреп калды.

Шунда йөгереп барып, тәрәзәне ачты.

— Фельтон! Болай булгач, мин котылдым! — дип кычкырып җибәрде миледи.

— Әйе, котылдыгыз, тик акрынрак сөйләшегез!..— диде Фельтон.— Минем әле рәшәткәнең тимерләрен кисәсем бар. Саграк булыгыз, ишектәге тәрәзәдән күреп алмасыннар сезне.

— Ходайның безне яклавы рас, Фельтон, ишектәге тәрәзәгә такта кактылар,— диде миледи.

— Яхшы анысы, ходай аларның акылын алган,— дип җавап кайтарды Фельтон.

— Мин нишләргә тиешмен соң? — дип сорады миледи.

— Берни дә эшләмисез, тәрәзәне генә ябыгыз. Урыныгызга ятыгыз, һич югы, чишенмичә генә ятып торыгыз! Эшемне бетергәч, мин тәрәзәне шакырмын. Тик сезнең миңа иярерлек хәлегез бармы соң?

— Бар, бар!

— Әярагыз?

— Авыртса да, йөрергә зыяны юк.

— Мин ымлауга ук әзер булып торыгыз.

Миледи тәрәзәне ябып, утны сүндерде, Фельтон киңәш иткәнчә, караватына ятып, юрганын ябынды. Давыл улаган авазлар аша ул тимер рәшәткәне кискән пычкы чыжлавын ишетте, ялт итеп яшен яшьнәгән саен тәрәзә пыяласының теге ягындагы Фельтон шәүләсен күрде.

Тынын көчкә-көчкә алып, бер сәгать буе караватында ятты. Бөтен тәне салкын тиргә батты, коридорда аз гына кыштырдаган тавыш ишетелсә дә, куркудан йөрәге чапаланып кысылыпкысылып куйды.

Еллар гомере белән тиңләшерлек сәгатьләр була шул.

Бер сәгатьтән Фельтон тагын тәрәзәне шакыды.

Миледи караватыннан сикереп торды да тәрәзәне ачты. Тәрәзә рәшәткәсенең ике тимере киселеп, кеше сыярлык ара ачылган иде.

— Сез әзерме?— диде Фельтон.

— Әйе. Үзем белән берәр нәрсә алыйммы соң?

— Булса, алтыныгызны алыгыз.

— Бар, бәхеткә каршы, үзем белән алып килгән алтынымны калдырганнар иде.

— Бик яхшы, мин судно яллап акчамны тотып бетергән идем инде.

— Мәгез,— дип, миледи Фельтонга бер янчык алтын тәңкә бирде.

Фельтон янчыкны алып, аска, стена буена ташлады.

— Хәзер инде төшәргә вакыт,— диде.

— Яхшы,— дип җавап бирде миледи.

Креслога басып, башын тәрәзәгә тыкты. Офицер егетнең

баудан ясалган баскычта упкын өстендә басып торганын күрде.

Беренче тапкыр йөрәген курку басып, үзенең хатын-кыз икәнлеген исенә төшерде.

Төпсез упкынны күреп коты алынды.

— Бөтен курыкканым шул иде,— дип куйды Фельтон.

— Монысы гына куркыныч түгел!.. Куркыныч түгел!..— дип сөйләнде миледи.— Төшкән чакта күземне йомармын.

— Миңа ышанасызмы? — дип сорады Фельтон.

— Сорап торасыз тагын!

— Кулыгызны миңа бирегез. Кушырыгыз. Сузыгыз. Менә шулай.

Фельтон аның кулларын башта яулык белән, аннары яулык өстеннән бау белән бәйләде.

— Нишлисез сез? — диде миледи сәерсенеп.

— Кулларыгызны минем муенга салыгыз да бернидән курыкмагыз.

— Минем аркада тигезлегегезне югалтсагыз, икебез дә ычкынып китеп бетәбез бит.

— Курыкмагыз, мин моряк.

Бер генә мизгел вакытны да әрәм итәргә ярамый иде; миледи куллары белән Фельтонны муеныннан кочаклады да аның булышлыгы белән тәрәзәдән чыкты.

Фельтон, әкрен генә, иплəп кенә баса-баса, баскычтан төшә башлады. Ике кеше авырлыгына карамастан, ургып-ургып искән җил баскычны һавада тирбәлдереп тора иде.

Фельтон кисәк кенә туктап калды.

— Ни булды? — дип сорады миледи

— Акрын! Ниндидер аяк тавышы ишетәм,— диде Фельтон.

— Безне күрделәр!

Беравыкка сүзсез калып, тыңлап тордылар.

Аннары Фельтон:

— Куркырлык бер нәрсә дә юк,— дип куйды.

— Кемнәр йөри соң анда?

— Патруль замокны карап-тикшереп йөри.

— Ә ул кайдан узарга тиеш?

— Нәкъ безнең астан.

— Безне күрәчәк бит ул.

— Яшен яшьнәп яктыртмаса, күрмәс.

— Баскычның очына бәрелеп китәр.

— Бәхеткә каршы, җиргә алты фут җитми ул.

— Әнә алар, йа раббым!

— Тыныгыз.

Алар җирдән егерме фут биеклегендә, селкенмичә, тынчарын кысып, асылынып тора бирделәр, бу вакытта исә аста, алар турысыннан, көлешә-көлешә сөйләшеп, солдатлар уза башлады.

Качаклар өчен иң куркыныч минут җитте.

Патруль узып китте. Аларның аяк атлавы һәм сөйләшүләре еракка китеп тына барды.

— Хәзер инде котылдык,— диде Фельтон.

Миледи тирән итеп бер сулу алды да һушсыз калды.

Фельтон тагын төшә башлады. Баскычның очына төшеп җиткәч, аяк басарга терәк калмаганлыктан, баскыч басмаларына куллары белән тотына-тотына төште; иң ахырында, соңгы басмага тотынып асылынуга, аяклары җиргә тиде. Иелеп, акча янчыгын алды да аны авызына капты.

Шуннан соң ул миледины кулына күтәреп, тиз-тиз генә, патруль киткәннән кире якка атлады. Озакламый дозор юлыннан борылып ике кыя арасына төште дә яр кырыена җиткәч сызгырып җибәрде.

Аңа да сызгырып җавап кайтардылар һәм бер биш минуттан диңгездә дүрт ишкәкче утырган көймә күренде.

Көймә ярга мөмкин кадәр якынрак килергә тырышты: ул тирә сай булганлыктан, ярга чыгып җитеп булмый иде. Фельтон, бик кадерле йөген беркем кулына да бирәсе килмәгәнлектән, үзе бил тиңентен суга керде.

Бәхетләренә каршы, давыл басыла башлады, шулай да диңгез өсте әле һаман дулкынлана, кайнап тора иде. Кечкенә генә бу көймә дулкыннар өстендә чикләвек кабыгы шикелле атына-атына тирбәлә иде.

— Шхунага киттек! Тизрәк ишегез! — дип боерды Фельтон.

Дүрт матрос ишкәк ишәргә керештеләр, эмма, диңгез бик каты дулкынланганлыктан, ишкәкләр көчкә-көчкә генә суны ишә иде.

Шулай да качаклар замоктан шактый ерагаеп баралар — хәзергә иң кирәге шул иде. Төне бик караңгы, көймәдән инде яр буе күренми диярлек, көймәне исә яр буеннан бигрәк тә күреп булмый иде.

Диңгез уртасында ниндидер бер кара нокта сыман нәрсә чайкалып тора — монысы шхуна иде.

Дүрт матрос каерылып-каерылып шхунага таба ишкән арада Фельтон башта милединың кулларын бәйләгән бауны, аннары яулыкны чиште.

Кулларын баудан ычкындыргач, учы белән диңгез суы алып, милединың битенә сипте.

Миледи тирән итеп сулады да күзен ачты.

— Мин кайда? — дип сорады.

— Сез котылдыгыз! — диде офицер егет.

— О! Котылганмын! — дип куйды миледи.— Әйе шул, әнә күк йөзе, менә диңгез! Сулаган һавам — ирек һавасы. Аһ!.. Рәхмәт сезгә, Фельтон, бик зур рәхмәт!

Егет аны күкрәгенә кысты.

— Минем кулларым нишләгән соң? — диде миледи сәерсенеп.— Эскәнҗәгә куеп кыскан кебек!

Миледи кулларын күтәреп күрсәтте: беләзек турылары чыннан да берни тоймаслык булып күгәреп чыккан иде.

Фельтон шул матур кулларга карап, ягымлы бер төс белән башын чайкый-чайкый:

— Шулай шул! — дип кенә көрсенеп куйды.

— Әй, юк нәрсә лә! Исемә төште хәзер! — диде миледи.

Аннары үз тирәсенә каранып күзе белән нәрсәдер эзли башлады.

— Монда ул,— диде Фельтон, алтын салган янчыкны аягы белән аңа табарак этәрде.

Алар шхунага якынлаштылар. Вахтада торучы матрос көймәдәгеләргә эндәште, көймәдән аңа җавап кайтардылар.

— Нинди судно бу? — дип сорады миледи.

— Шхуна бу, сезнең өчен мин ялладым.

— Мине кая илтә соң ул?

— Кая теләсәгез, шунда илтә, тик сез мине Портсмутта төшереп кенә калдырыгыз.

— Портсмутта нәрсә эшләргә җыенасыз? — дип сорады миледи.

— Лорд Винтерның боерыгын үтим,— диде Фельтон күңелсез генә елмаеп.

— Нинди боерык ул?

— Төшенмисезмени?

— Юк шул. Зинһар, аңлатып бирегез әле.

— Миңа бүтән ышанмыйча, ул сезне үзе сакларга булды, ә мине үзе урынына Бекингэмга сезне сөргенгә сөрү турындагы боерыкка кул куйдырырга җибәрде.

— Үзе сезгә ышанмагач, ничек ул боерыкны илтергә кушты соң?

— Мин нәрсә илткәнемне белергә тиешмени?

— Дөрес анысы. Шуңа күрә сез Портсмутка барасызмы?

— Ашыгырга кирәк миңа: иртәгә егерме өчесе, Бекингэм флот белән китәчәк.

— Иртәгә китәмени? Кая китә?

— Ларошельгә.

Миледи, гадәттәге сабырлыгын җуеп:

— Анда китәргә тиеш түгел ул! — дип кычкырып әйтеп куйды.

— Борчылмагыз, китмәс,— диде Фельтон.

Миледи сөенеченнән тетрәнеп китте — ул егетнең йөрәк түрендә яткан мәгънәне аңлады: анда Бекингэм үләчәк дип язылган иде.

— Фельтон... син Иуда Маккавей кебек бөек кеше! Син үлсәң, мин дә синең белән бергә үләм — минем сиңа сүзем шул.

— Әкренрәк сөйләшегез! Килеп җитәбез,— дип искәртте аны Фельтон.

Көймә чыннан да шхуна янына килеп җиткән иде инде.

Иң алдан Фельтон траптан шхунага менде дә миледига кулын сузды, ә матрослар аңа менәргә яннан булыштылар, чөнки диңгез һаман давыллый иде әле.

Беравыктан алар палубага менеп басканнар иде инде.

— Капитан, мин әйткән ханым менә шушы була, аны исән-сау килеш Франциягә кайтарып җиткерергә кирәк,— диде Фельтон.

— Мең пистольгә,— диде капитан.

— Мин сезгә биш йөзен бирдем бит инде.

— Дөрес.

Шунда миледи, алтын салган янчыкны кулына алып:

— Менә калган биш йөзе,— дип сүзгә кушылды.

— Юк, әйткән сүземне бозмыйм мин, бу егеткә мин сүз бирдем: калган биш йөзен Булоньга барып җиткәч кенә алам,— диде капитан бу сүзгә каршы.

— Ә Булоньга барып җитәрбезме соң без?

— Исән-сау барып җитәрбез. Минем исемем Джек Бутлер икәнлеге чын булган кебек, барып җитүебез дә шулай булыр,— диде капитан.

— Алайса шул: әгәр сүзегездә торсагыз, мин сезгә биш йөз пистоль генә түгел, мең пистоль бирәм.

— Ура, гүзәл ханым! Сезнең кебек пассажирларны ходай күбрәк бирсен иде миңа! — дип кычкырды капитан.

— Ә хәзер сез безне бухтага илтегез... Кайсы бухтага илтергә дип сөйләшкәнебезне хәтерлисездер? — диде Фельтон.

Бу сүзгә җавап итеп капитан тиешле курс алырга боерык бирде һәм иртәнге сәгать җиделәр тирәсендә кечерәк бер судно Фельтон әйткән бухтага килеп җитеп якорь ташлады.

Юлда барган вакытта Фельтон миледига барысын да: Лондонга китәсе урында шушы судноны яллап йөрүен, аннары кире кайтуын, таш ярыкларына тимер каптыргычлар куеп, шуларга баса-баса, стенага менүен һәм, ниһаять, тәрәзә рәшәткәсенә менеп җиткәч, баудан ясалган баскыч бәйләүләрен сөйләп бирде. Шуннан калганнары миледига билгеле иде инде.

Миледи исә Фельтонның күңелендәге ниятен ныгыта төшәргә тырышты. Ләкин ул хакта сөйли башлау белән үк миледи бу фанатик егетне хуплап дәртләндерүдән бигрәк тыя төшәргә кирәклеген төшенде.

Болай дип сүз куештылар алар: миледи Фельтонны сәгать унга хәтле көтәчәк тә, егет шул вакытка килеп җитмәсә, миледи юлга чыгачак.

Әгәр инде егет иректә калса, Франциядә Бетюндагы кармелиткалар монастыренда очрашырга булдылар.

## XXIX

## *1628 ЕЛНЫҢ 23 АВГУСТЫНДА ПОРТСМУТТА БУЛГАН ХӘЛЛӘР*

Фельтон, болай йөреп керергә генә чыккан чакта туганы белән хушлашкан кебек, милединың кулын үбеп кенә саубуллашты.

Килеш-килбәте белән ул башка вакытлардагы шикелле тыныч күренә, тик күзләре генә гадәтендә булмаганча эчтән кызышкан-көйрәгән сыман ялтырый иде. Йөзе гадәттәгедән агара төшкән, иреннәре кысылып тора, эчендәге күңелсез-ямьсез кичерешләрен сиздереп, сүзен кыска-кыска һәм өзек-өзек итеп кенә әйтә иде.

Корабтан көймә белән ярга чыккан чагында Фельтон күзен дә алмыйча һаман миледига карап барды, миледи да, палубада басып торган килеш, аңа карап озатып калды. Хәзер инде алар икесе дә артыбыздан куа килерләр дип курыкмыйлар: замоктагы миледи булмасенә сәгать тугыздан да иртә кермиләр, ә замок белән Лондон арасын ат белән өч сәгать узарга кирәк иде.

Фельтон, ярга төшкәч, калку сырты буйлап кыя түбәсенә менде дә, соңгы тапкыр саубуллашып миледига кул болгагач, калага таба борылды.

Ярдан киткән саен юл аска төшә бара иде, Фельтон инде йөз адым чамасы узгач та, шхунаның мачтасы гына күренде.

Алда, ярты миль чамасында, иртәнге томан эченнән Портсмутның манаралары белән портлары калкып күренә башлады. Фельтон шунда таба ашыкты.

Портсмутның теге ягында диңгез өсте кораблар белән тулган; аларның мачталары, кышкы салкында ялангачланып калган тирәк агачлары сыман, җилдә чайкалгалап тора иде.

Фельтон, кызу-кызу атлаган шәпкә, Яков VI һәм Карл I фаворитының чын һәм ялган гаепләрен күңеленә китереп уйлап барды — болар арасында аның үзе ике ел буена уйланып туплаганнары да һәм Бекингэмга пуританнар сылтаган гаепләр дә бар иде.

Бу министрның халыкка мәгълүм җинаятьләрен, ягъни Европага шаулаган җинаятьләрен, миледи сөйләгән яшертен шәхси җинаятьләре белән янәшә куеп карагач, Фельтон бер Бекингэм йөзендәге ике кеше тормышының халыкка билгеле булмаганы гаеплерәк дип тапты. Моның хикмәте шунда — кырмыска белән чагыштырганда да күзгә чак-чак күренерлек тузан бөртекләре зурайткыч пыяла аша коточкыч дәү булып күренгән кебек, Фельтонның йөрәгендә капыл гына дөрләп кабынган сәер мәхәббәте леди Винтер уйлап чыгарган әшәке гаепләрне тау чаклы итеп күпертеп күрсәтә иде.

Кызу-кызу атлаганга гайрәте аның тагы да кыза төште. Тегендә, артта, үзе сөйгән, дөресрәге, илаһи бер зат итеп табынган хатынның бик яман үч корбаны булу ихтималы, баягы кичерешләре, ару-талуы — шулар барысы аның бөтен рухын кузгатып әсәрләндереп җибәргән иде.

Портсмутка ул иртәнге сәгать сигезләр тирәсендә килеп керде. Бөтен кала халкы инде торып аякка баскан; урамнарда һәм гаваньда барабан кагалар, китүче гаскәрләр диңгезгә таба юл тота иде.

Фельтон, тузанга һәм тиргә батып, Адмиралтействога килеп

житте; гадәттәге ак чырайлы йөзе хәзер инде эсседән һәм ачу-ярсудан кызышып-кызарынып чыккан иде. Сакчы аны кертмәскә теләгәч, Фельтон каравыл башлыгын чакырып китертте дә, кесәсеннән үзе тапшырасы боерыкны чыгарып:

— Лорд Винтерның ашыгыч йомышы белән килдем,— диде.

Герцогның иң якын дусларыннан берсе булган лорд Винтерның исемен ишеткәч, каравыл башлыгы диңгез офицеры мундиры кигән Фельтонны үткәреп җибәрергә кушты.

Фельтон сарайга йөгерде.

Ул вестибюльгә кергән чакта шунда тыны-көне беткән, тузанга баткан тагын бер кеше килеп керде — аның чаба-чаба хәлдән тайган почта аты баскыч төбенә килеп туктауга ук җиргә тезләнде.

Фельтон белән әлеге кеше герцогның тулы ышанычлысы булып саналган камердинер Патрикка икесе берьюлы мөрәҗәгать иттеләр.

Фельтон, мине барон Винтер җибәрде, диде, әлеге кеше үзен кем җибәргәнлеген әйтмәде, кем икәнлегемне герцогның үзенә генә әйтә алам, диде. Һәркайсы алданрак керүне дәгъвалады.

Лорд Винтер эш буенча да, дус буларак та герцог белән гел аралашып торганлыктан, Патрик ул җибәргән кешене алдан кертүне кулайрак санады. Әлеге атчабарга бераз сабыр итәргә туры килде, болай тоткарлануына аның бик яман ачуы килгәнлеге күренеп тора иде.

Камердинер, Фельтонны ияртеп, зур зал аша узды — монда принц Субиз җитәкчелегендә килгән Ларошель халкы делегациясе герцогның кабул иткәнен көтеп утыра иде,— аннары аны бер бүлмә ишеге төбенә алып килде. Бу бүлмәдә Бекингэм әле яңарак кына ваннага кереп чыккан, гадәтенчә бик әһәмиятле эше итеп санаган туалетын төгәлләп килә иде.

— Лейтенант Фельтон. Лорд Винтер йомышы белән килгән,— диде Патрик.

— Лорд Винтер йомышы белән?! — дип кабатлады Бекингэм.— Кертегез.

Фельтон бүлмәгә килеп керде. Шул минутта Бекингэм алтынлап тукылган зиннәтле халатын диван өстенә ташлады да энҗеләп чиккән зәңгәр бәрхет камзулын кия башлады.

— Нигә барон үзе килмәде? — дип сорады.— Бүген иртән мин аны көткән идем,— диде.

— Сез галиҗәнапка әйтергә кушты ул: килә алмавы өчен гафу үтенә, чөнки аның үзенә замокта сакта торырга туры килә,— дип җавап бирде Фельтон.

— Әйе, әйе, беләм. Аның бер тоткын хатыны бар.

— Сез галиҗәнап белән мин әнә шул тоткын хатын турында сөйләшмәкче идем.

— Сөйләшегез соң!

— Минем сезгә әйтәсе сүземне сездән башка беркем дә ишетергә тиеш түгел, милорд.

— Чыгып торыгыз әле, Патрик, шулай да ерак китмәгез, мин кыңгырау чыңлату белән керерлек булыгыз. Сезне хәзер чакырырмын,— диде Бекингэм.

Патрик чыгып китте.

— Икәү генә калдык, әфәндем. Әйтегез,— диде Бекингэм.

— Милорд, моннан берничә көн элек барон Винтер сезгә хат язган иде, сездән Шарлотта Баксон исемле бер яшь хатынны сөргенгә сөрү турындагы боерыкка кул куюыгызны үтенгән иде.

— Шулай, әфәндем, мин аңа ул боерыкны үзегез китерегез яисә кеше аркылы җибәрегез дигән идем, боерыкка кул куям мин.

— Менә ул боерык, милорд.

— Китерегез.

Герцог Фельтон кулыннан кәгазьне алды да тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты. Моның лорд Винтер әйткән боерык икәнлегенә ышангач, кәгазьне өстәлгә куйды һәм, имза салырга җыенып, кулына каләм алды.

— Гафу итегез, милорд,— диде Фельтон, герцогның кулыннан тотып,— сез галиҗәнапка мәгълүм микән: ул яшь хатынның чын исеме Шарлотта Баксон түгел бит.

Герцог:

— Әйе, әфәндем, анысы миңа мәгълүм,— диде дә каләмен карага манып алды.

— Димәк, сез, галиҗәнап, аның чын исемен беләсез?

— Әйе, беләм.

Герцог каләмен кәгазь өстенә китерде. Фельтонның чырае агарынып китте.

— Аның чын исемен белә торып, сез, галиҗәнап, боерыкка кул куясызмы?

— Әлбәттә, уйлап та тормыйм.

— Сүзнең леди Винтер турында барганлыгы сез галиҗәнапка мәгълүм булуына ышанып бетә алмыйм мин...— дип, тагы да кырысрак һәм өзек-өзек тавыш белән дәвам итте Фельтон.

— Миңа бик яхшы мәгълүм ул, тик сезнең шуны белүегез гаҗәпләндерә мине!

— Һәм сез, галиҗәнап, һич уңайсызланмыйча ул боерыкка кул куясызмы?

Бекингэм тәкәббер бер кыяфәт белән егеткә күтәрелеп карады.

— Әфәндем, сез миңа бик сәер сораулар бирәсез, мин сезгә җавап кайтарып бик зур түбәнчелек күрсәтәм!

— Җавап бирегез, галиҗәнап. Ихтимал, хәл сез уйлаганнан күп тапкыр җитдирәктер,— диде Фельтон.

Бекингэм егетне, лорд Винтер кушуы буенча килгәч, аның исеменнән сөйли дип белеп, йомшара төште.

— Бер дә уңайсызланмыйча кул куям мин менә,— дип җавап кайтарды ул.— Миледи Винтерның зур бер җинаятьче икән-

леге баронга да, миңа да мәгълүм, аны сөргенгә җибәреп кенә җәзалау — гаебен кичерү белән бер ул.

Герцог каләмен кәгазьгә тидерде.

— Сез бу боерыкка кул куймаячаксыз, милорд! — диде Фельтон, герцогка таба бер адым атлап.

— Мин бу боерыкка кул куймаячакмын? Ни өчен? — дип гаҗәпләнә калды Бекингэм.

— Чөнки сез үз күңелегезгә күз саласыз да миледины гаделлек белән аклыйсыз.

— Гаделлек аны Тайбернга сөрергә кушар иде. Миледи — бик әшәке бәндә.

— Галиҗәнап, миледи — фәрештә ул, сез анысын бик яхшы беләсез. Мин сездән аңа ирек бирүегезне сорыйм.

— Акылыгыздан яздыгызмы әллә сез?! Ничек әле сез минем белән болай сөйләшергә җөрьәт итәсез?

— Мине гафу итегез, милорд, мин инде үз белгәнемчә сөйлим, тыелыбрак калырга да тырышам. Тик сез, милорд, үзегезнең нәрсә эшләргә җыенуыгызны да уйлагыз, чама дигәнне узып китүдән куркыгыз.

— Ни дигән сүз бу?.. Ярабби! Бу мине куркыта башлады түгелме?! — диде Бекингэм каушый калып.

— Юк, милорд, мин сездән янә үтенеп сорыйм һәм әйтәм: түзем касәсе тулып ташысын өчен бер тамчы да җитә, кечкенә генә бер гаеп тә ходай тарафыннан барлык җинаятьләре кичерелгән кеше башына бәхетсезлек китерүе ихтимал.

— Фельтон әфәнде, рәхим итеп моннан чыгып китегез дә сак астына алыныгыз,— дип боерды Бекингэм.

— Рәхим итеп мине тыңлап бетерегез милорд. Сез ул яшь кызны алдап, бик каты кимсеткәнсез, аны мәсхәрә иткәнсез. Аңа карата кылган бу яманлыкны оныттырыгыз, сез аңа бернинди комачаусыз кайтып китәргә ирек бирегез, шуннан бүтән берни сорамыйм мин сездән.

Бекингэм, Фельтонга шаккатып караган хәлдә, һәр сүзенә басым ясап:

— Бүтән берни сорамыйсыз?! — диде.

— Милорд,— диде Фельтон сөйләгән саен кыза барып,— сак булыгыз, милорд, сезнең башбаштаклыгыгыздан бөтен Англия гаҗиз булды инде. Милорд, сез король властеннан файдаланып, бик күп яманлыклар кылдыгыз, аны бөтенләй диярлек үз кулыгызга алдыгыз. Милорд, сез кешеләрнең дә, ходайның да гайрәтен чигердегез. Ходай сезгә җәзасын соңрак бирер, ә мин сезгә бүген җәза бирәм.

— Монысы инде чамадан узды! — дип кычкырды Бекингэм һәм ишеккә таба атлый башлады.

Фельтон аның юлына аркылы төште.

— Яхшылык белән үтенеп сорыйм сездән: леди Винтерны азат итү турындагы боерыкка кул куегыз; ул хатынның үзегез мәсхәрә иткән хатын икәнлеген исегезгә төшерегез,— диде ул.

— Чыгып китегез моннан, әфәндем! Югыйсә хәзер үк сакчылар чакырып аяк-кулларыгызга богау салдырам.

Фельтон, көмеш инкрустацияле кечкенә өстәлгә ташланып, герцогка кыңгыравын чыңлатырга ирек бирмичә:

— Беркемне дә чакырмыйсыз. Сак булыгыз, милорд, сез хәзер ходай кулында,— диде.

Бекингэм, туп-туры ярдәмгә чакырмаса да, күрше бүлмәдәге кешеләрнең игътибарын җәлеп иттерү өчен, тавышын күтәрә төшеп:

— Явыз иблис кулында димәкче буласыздыр,— дип кычкырды.

— Леди Винтерны азат итү турындагы боерыкка кул куегыз, милорд, кул куегыз,— дип таләп итте Фельтон, герцогка ниндидер кәгазь сузып.

— Сез миннән көчләп кул куйдырмакчы буласызмы?! Мине мыскыл итәсезме?! Әй, Патрик!

— Кул куегыз, милорд!

— Һич!

— Алаймы?

Герцог:

— Коткарыгыз! — дип кычкырды да кылычына үрелде.

Ләкин Фельтон аңа кылычын чыгарырга ирек бирмәде: теге, миледи үзен яралаган пычакны ул, кадарга әзерләп, куен турысында тотып тора иде — бер сикерүдә герцогка ташланды.

Шул чакны кабинетка Патрик килеп керде.

— Милорд, Франциядән хат бар! — дип кычкырды ул.

Бекингэм бөтен дөньясын онытып, хатның кемнән булуын гына уйлый-уйлый:

— Франциядән?! — дип кычкырды.

Фельтон нәкъ әнә шул мизгелдән файдаланып калды — пычакны сабына чаклы герцогның янтыгына батырды.

— Аһ, хыянәтче! Үтердең бит мине!..— дип кычкырып җибәрде Бекингэм.

— Үтерәләр! — дип аваз салды Патрик.

Фельтон, качарга чамалап, як-ягына күз салды һәм ачык ишекне күреп, күрше залга ташланды,— анда, әйткәнебезчә, Ларошель депутациясе Бекингэмның кабул иткәнен көтеп утыра иде,— шул залдан йөгереп үтте дә баскычка таба чапты, әмма баскыч башында лорд Винтерга килеп бәрелде; лорд Винтер, Фельтонның үлек чырае төсле агарган йөзен, ялт-йолт килгән күзләрен һәм куллары белән битендәге кан тапларын күргәч, аны бугазыннан эләктереп алды да кычкырып җибәрде:

— Белгән идем мин моны! Сизгән идем, үкенечкә каршы, бер минутка соңрак сиздем шул. Ай, бәхетсезлегем! Бәхетсезлегем!

Фельтон аз гына да каршылык күрсәтмәде. Лорд Винтер аны сакчылар кулына тапшырды, алары, нинди боерык буласын көтеп, Фельтонны диңгез ягына караган кечерәк бер террасага алып киттеләр, лорд Винтер исә ашыга-ашыга Бекингэм кабинетына китте.

Герцогның кычкырганын, Патрикның ярдәмгә чакыруын ишетеп, Фельтон белән вестибюльдә очрашкан кеше кабинетка йөгереп килеп керде.

Герцог калтыранган кулы белән ярасын тотып диванда ята иде.

— Ла Порт,— диде герцог үлеп барган тавыш белән,— Ла Порт, сине ул җибәрдеме?

— Әйе, галиҗәнап, тик мин соңгарак калдым бугай,— диде Анна Австрияленең турылыклы хезмәтчесе.

— Әкренрәк, Ла Порт! Сүзегезне ишетеп калулары ихтимал. Патрик, беркемне дә кертмәгез. Аһ, аның миңа ниләр әйтергә кушканын белә алмый калам инде. И аллам, үләм инде мин!

Шулай дию белән герцог һуштан язды.

Ул арада лорд Винтер, Ларошель кешеләре, экспедиция гаскәрләренең башлыклары һәм Бекингэм свитасы офицерлары төркемнәре белән бүлмәгә килеп керделәр; бөтен яктан аһ та уһ иткән тавышлар ишетелде. Сарай эчен сыктап елаган, аһ орган авазлар белән тутырган кайгы хәбәре озакламый аннан тышка чыгып, бөтен шәһәргә таралды.

Гөрселдәгән туп тавышы көтелмәгән зур бер хәл булганлыгын хәбәр итте.

Лорд Винтер, чәчләрен йолкып:

— Бер генә минутка бит! Бер генә минутка! Ай аллам, ай аллам! Нинди зур бәхетсезлек! — дип аһ орды.

Чыннан да, иртәнге сәгать җидедә аңа, замокның бер тәрәзәсе турысында баудан ясалган баскыч асылынып тора, дип килеп әйттеләр. Ул шундук миледи бүлмәсенә йөгерде. Килеп керсә, бүлмәдә беркем юк, тәрәзәсе ачык, рәшәткә тимерләрен кискәннәр иде; шуннан соң ул д'Артаньянның йомышчысы аша, үзен искәрткәнлеген исенә төшерде, герцог өчен куркып йөрәге калтырана башлады, абзарга йөгерде, ат иярләп биргәнне көтеп тормастан, беренче туры килгәненә менеп атланды да җанфәрманга чаптырып Адмиралтействога килеп җитте, ишегалдына кергәч, атыннан сикереп төште дә баскычтан йөгереп менеп китте һәм, әйтеп үткәнебезчә, баскыч башында Фельтонга килеп бәрелде.

Шулай да герцог исән иде әле, ул яңадан һушына килеп күзен ачты, һәм янына җыелган кешеләрнең йөрәгенә өмет җылысы керде.

— Әфәнделәр, мине Ла Порт һәм Патрик белән генә калдырыгызчы,— диде ул.— Ә, сезмени бу, Винтер! Сез бүген иртән минем янга әллә нинди бер дивана кеше җибәргәнсез, күрәсезме, нишләтте ул мине!

— Һай, милорд! — дип кычкырып җибәрде барон,— гомерем буе онытылмаслык үкенеч-кайгы булачак бу минем өчен.

— Алай диюең дөрес булмас, Винтер дустым,— диде Бекингэм, аңа кулын сузып.— Мин алай икенче бер кешене гомере буена кайгыга салырлык бер кешене дә белмим... Зинһар, безне үзебезне генә калдырып тор.

Барон үкси-үкси чыгып китте.

Бүлмәдә җәрәхәтле герцог, Ла Порт һәм Патрик кына калдылар.

Герцогның якыннары һаман да табипны эзләп таба алмыйлар иде әле.

Анна Австрияләнең тугрылыклы хезмәтчесе, диван каршына тезләнгән килеш:

— Сез яшисез әле, милорд, яшисез әле,— дип тәкрарлады.

— Ниләр язган ул миңа? — дип сорады Бекингэм зәгыйфь кенә тавыш белән; ул каты әрнү-сызлауга көч-хәл белән түзеп, кан эчендә ятса да, яраткан кешесе турында сорашырлык көч тапты.— Ниләр язган ул миңа? Хатын укы әле.

— Алай ярыймыни, милорд?! — диде Ла Порт куркуга төшеп.

— Тыңла инде, Ла Порт. Миңа вакыт әрәм итәргә ярамаганны күрмисеңмени?

Ла Порт хатның печәтен куптарып, пергаментны герцогның күзе янынарак китерде, ләкин Бекингэм анда язылган сүзләрне укырга тырышып караса да таный алмады.

— Укы инде, укы, күзем күрми. Укы! Озакламый мин бөтенләй ишетмәс тә булырмын, бәлки; аның миңа ни язганын белмичә үлеп тә китәрмен.

Ла Порт, шуннан соң инде карышмастан, хатны укырга кереште:

«Милорд!

Сездән бик гозерләп сорыйм: мин сезне белә башлаганнан бирле сезнең аркада һәм сезнең хакка бик күп кыен күрдем инде: әгәр сезгә минем тынычлыгым кадерле булса, Франциягә каршы кораллануыгызны туктатыгыз һәм сугышны бетерегез. Бу сугыш хакында, дин ул тышкы сәбәп кенә дип ачыктан-ачык әйтәләр, ә үзара шыпырт кына, моның чын сәбәбе — сезнең мине яратуыгыз, диләр. Бу сугыш Франция белән Англиягә зур бәла-казалар тудырып кына калмастан, сезнең үзегезгә дә, милорд, бәхетсезлек китерүе ихтимал. Анысы инде минем өчен бик зур кайгы булыр иде.

Үзегезне берүк саклый күрегез, сезне үтерүләре ихтимал. Сезнең исәнлегегез, үзегезне дошман итеп күрергә мәҗбүр булмый башлагач, минем өчен бик кадерле булачак.

Сезне якын итүче

*Анна*».

Бекингэм соңгы көчен җыеп, шушы хатны тыңлап ятты, аннары, хат укылып беткәч, хаттан бик кәефе киткән сыман:

— Үз телегез белән миңа бер сүз дә әйтә алмыйсызмы, Ла Порт? — дип сорады.

— Әйе, әйтәм, әйтәм, галиҗәнап: королева сезгә бик сак булсын дип әйтергә кушты, аңа әйткәннәр: сезне үтерергә телиләр икән.

— Шул гынамы?.. Шул гынамы? — диде Бекингэм түземсезләнеп.

— Сезне әүвәлгечә үк яратуын да әйтергә кушты.

— Аһ!.. Йа ходам!..— дип куйды Бекингэм.— Димәк, минем үлүемә ул тәгаен кайгырачак!..

Ла Порт күз яшьләрен түгеп еларга кереште.

— Патрик, асылташлар салып торткан теге тартманы китерегез әле,— диде герцог.

Патрик тартманы алып килде, Ла Порт аның королева тартмасы икәнлеген күрү белән үк таныды.

— Ә хәзер энҗе белән аның вензеле чигелгән ак атлас янчыкны китерегез.

Патрик аның бу үтенечен дә үтәде.

— Мәгез, Ла Порт,— диде Бекингэм,— шушы тартма белән шушы ике хат миңа дуслык билгесе итеп биргән бердәнбер залоглары бу. Боларны олуг ханымга кайтарып тапшырыгыз һәм, минем хакта соңгы истәлек итеп... (ул үз тирәсеннән күзе белән ниндидер кадерле бер әйбер эзләде)... шулар янына...

Герцог янә күзе белән нәрсәдер эзләргә кереште, әмма әҗәле алдыннан томанланып киткән карашы Фельтон кулыннан төшеп калган пычакны гына шәйләде. Йөзенә кып-кызыл кан җәелгән пычак әле һаман буланып тора иде.

— Шуның янына менә бу пычакны да кушыгыз! — дип герцог көчкә сүзен әйтеп бетерде һәм Ла Портның кулын кысты.

Шуннан соң ул, соңгы көчен җыеп, янчыкны тартма төбенә салды, шунда ук пычакны да куйды, Ла Портка ымлап кына инде бүтән сөйләшә алмавын белгертте. Аннары җан газабы белән тартыша башлап,— хәзер инде аның бирешмәслек көче калмаган иде, — диваннан паркет идәнгә тәгәрәп төште.

Патрик бик каты кычкырып җибәрде.

Бекингэм соңгы тапкыр елмаерга итте, әмма әҗәле аның бу теләгенә ирек бирмәде, һәм елмаюы, соңгы тапкыр яратып үбүе сыман, йөзендә катып калды.

Шул минутта, каушап-дулкынланып, герцогның табибы килеп керде, ул инде адмирал корабына утырган булган, аны шуннан барып алырга туры килгән.

Табип, герцог янына килеп, кулын тотып карады да кире төшерде.

— Өмет юк, герцог үлгән,— диде.

— Үлде, үлде! — дип кычкырды Патрик.

Аның тавышына залдагы барлык кеше бүлмәгә килеп керде һәм бөтенесе каушап-шаккатып аһ-уһ итә, кайгы-хәсрәттән ачына-өзгәләнә башлады.

Лорд Винтер, Бекингэмның җан биргәнлеген күрү белән, Фельтон янына йөгерде — солдатлар аны әле һаман сарай террасасында саклап торалар иде.

— Кабахәт җан! — диде ул егеткә. Бекингэм үлгәннән соң Фельтон янә тынычланган иде һәм ул соңыннан да шулай сабыр канлы булып калды бугай.— Кабахәт җан! Нишләдең син?

— Үзем өчен үч алдым,— диде Фельтон.

— Үзең өчен! — диде барон ачуы кайнап.— Ичмасам, әйт:

шул явыз хатынның коралы булдым, диген. Әмма мин сиңа ант итеп әйтәм: ул хатынның соңгы явызлыгы булыр бу!

— Сез ни әйтергә телисездер,— мин аңламыйм,— диде Фельтон сабыр гына,— һәм мин сезнең кем турында әйтүегезне дә белмим, милорд. Герцог Бекингэмны миңа капитан дәрәҗәсе бирү хакындагы сезнең үтенечегезне ике тапкыр кире какканы өчен үтердем мин. Гаделсезлегенә күрә җәзасын алды, менә шул.

Винтер, Фельтонны бәйләүче солдатларга караган хәлдә, бу кадәр гамьсезлеккә исе китеп, шаккатып торды.

Әмма Фельтонның бу гамьсез чыраеннан аны бер нәрсә борчыганлыгы сизелә. Беркатлы пуритан, колагына берәр тавыш чалынган саен, милединың аяк атлавын һәм тавышын ишеткән кебек була, хатын аның кочагына ташланып, үзенең гаепле икәнен әйтергә һәм егет белән бергә җан бирергә киләдер кебек тоела иде.

Шунда ул, кинәт калтыранып куеп, үзе басып торган террасадан бөтен киңлеге белән җәелеп күренгән диңгез өстендәге ниндидер бер нокта чаклы гына нәрсәгә күзен төбәде. Шул кадәр арадан башка бер кеше дулкын өстендә чайкалган акчарлак дип кенә белерлек нәрсәне ул моряклярга хас үткен күзе белән күреп алды — Франция ярларына таба китеп барган шхунаның җилкәне иде ул.

Егет агарынып китте, ярылырга җитешкән йөрәгенә кулын китереп куйды һәм шунда милединың аңа хыянәт иткәнлеген аңлады.

— Сездән соңгы тапкыр бер яхшылык сорыйм, милорд! — дип мөрәҗәгать итте ул баронга.

— Нинди яхшылык?

— Вакыт күпме икәнлеген әйтмәссезме?

Барон кесәсеннән сәгатен чыгарды.

— Тугыз туларга ун минут,— диде.

Миледи сәгать ярымга алданрак китеп барган: бик зур фаҗига булганлыгын белгертеп туп ату белән, ул шхунага кузгалып китәргә боерык биргән иде.

Чалт иткән аяз күк астында, ярдан әллә кайда еракта, шхуна Франциягә таба китеп бара иде инде.

— Ходай шулай кушкандыр,— диде Фельтон фанатикларча бер карусызлык белән, шулай да үзе төртке чаклы гына булып күренгән әлеге шхунадан күзен ала алмады, шунда ул аның палубасында үзен үлемгә дучар иткән әлеге хатынның ак шәүләсен дә күрә кебек тоелгандыр, бәлки.

Лорд Винтер, Фельтонның карашын күзәтеп торып, аның газаплы чыраена күз салды да егетнең бөтен кичерешен аңлады.

— Башта җәзаны ялгызың гына алырсың, әшәке җан,— диде ул Фельтонга; егет инде, һаман диңгезгә караган килеш, үзен әйдәкләүче солдатларга бер дә карышмыйча китә башлаган иде,— әмма, яраткан энемнең истәлеге хакына ант итеп әйтәм: синең ул дустың качып котылмаячак.

Фельтон, бер сүз эндәшмәстән, башын иеп китеп барды.

Лорд Винтер исә йөгерә-йөгерә баскычтан төште дә гаваньга ашыкты.

## XXX

## ФРАНЦИЯДӘ

Англия короле Карл I Бекингэмның үлүен белгәч тә иң курыкканы бу яман хәбәр Ларошель кешеләренең рухын төшермәгәе дигән шиге булды; шуңа күрә ул, Ришельеның мемуарларында әйтелгәнчә, бу хәбәрне аларга озаграк белгертми торырга тырышты; дәүләтендәге бөтен гаваньнарны яптырып, Бекингэм хәзерләгән армия кузгалып киткәнче диңгезгә бер корабны да чыгармаска әмер бирде; Бекингэм үлгәннән соң армияне озатып җибәрү эшен король үзе күзәтеп-тикшереп тора башлады.

Аның болай катгый тыюы шул кадәргә җитте ки, хәтта үзе белән саубуллашып инде китәргә җыенган Дания илчеләрен һәм Кушма Нидерландка Карл I кире кайтарган Ост-Һинд корабларын Флиссенгенга алып китәргә тиешле Голландия илчесен дә Англиядән җибәртмәде.

Тик король бу боерыгын әлеге фаҗигале хәл булып биш сәгать узгач, ягъни көндезге сәгать икедә генә биргәнлектән, ике кораб гаваньнан чыгып өлгерде; берсе, белгәнебезчә, миледины утыртып алып китте. Ул инде нинди хәл булганлыгын сизенгән иде, адмирал корабының мачтасына кара флаг күтәрелгәнен күргәч, аның бу хәлгә ышанычы тагы да ныгый төште.

Икенче корабка килгәндә исә, анысына кем утырган, ничек китеп барганлыгын соңрак сөйләрбез.

Хәер, бу вакыт эчендә Ларошель янындагы лагерьда бернинди яңалык булмады; тик, гадәтенчә, лагерьда бигрәк тә эче пошкан король генә беркемгә сиздермичә Сен-Жерменга китеп, шунда изге Людовик көнен уздырырга карар итте һәм үзе өчен кардиналның егерме мушкетердан сак оештыруын үтенде. Корольнең эч пошуы ара-тирә кардиналга да йоккалап куя иде. Унбишенче сентябрьгә кайтып җитәм дип сүз биргән ярдәмчепатшасына инде бик риза булып ял бирде ул.

Де Тревиль әфәнде, кардинал хәзрәтләреннән шушы хәбәрне алгач, юлга җыенды һәм, ниндидер сәбәпләр аркасында дусларының Парижга бик кайтасылары килүен, хәтта зарури бер ихтыяҗ тоюларын белеп, аларны король сагына кертте.

Безнең дүрт егет бу хәбәрне де Тревиль әфәндедән соң чирек сәгать узгача ук белделәр, чөнки иң элек бу яңалыкны ул аларга хәбәр итте. Менә шунда инде д'Артаньян кардиналның аңа мушкетерлыкка күчәргә рөхсәт итеп яхшылык эшләвенең кадерен аеруча тойды. Шул хәл булмаган булса, д'Артаньян лагерьда торып калыр, иптәшләре исә китеп барырлар иде.

Аларның Парижга ни өчен кайтасылары килүен әйтеп тә торасы юк: Бонасье ханымга Бетюн монастырендә үзенең кан дошманы миледи белән очрашу бик хәтәр булачак иде. Шуңа күрә, әйткәнебезчә, Арамис Турдагы тегүчесе Мари Мишонга шундук хат язды. Бу тегүче ханымның зур гына танышлары

бар, ул королевадан Бонасье ханымга монастырьдан чыгып Лотарингиягә яисә Бельгиягә китәр өчен рөхсәт сорап ала ала икән. Җавап хаты озак көттермәде, тугызмы-унмы көннән соң Арамис мондый хат алды:

«Сөекле тудыкам!

Менә сезгә апамның Бетюн монастыреннан яшь асрау кызны алыр өчен биргән рөхсәте; үзегезнең фикерегезчә, ул монастырьның һавасы әлеге кыз өчен зарарлы икән. Апам бу рөхсәтне сезгә бик теләп җибәрә, чөнки бик булдыклы бу кызны ул бик ярата, кирәк була калса, киләчәктә дә аңа ярдәм итәрмен дип өметләнә.

Сезне үбеп,
*Мари Мишон».*

Шушы хатка түбәндәгечә язылган рөхсәт кәгазе дә теркәлгән иде:

«Бетюн монастыре назирәсе шушы хатны тапшыручы кеше карамагына монастырьга минем тәкъдимем белән кереп, минем химаячелегемдә яшәгән хатынны биреп җибәрсен.

*Анна.*
Луврда, 1628 елның 10 августы».

Арамисның королеваны үзенең апасы дип атаган тегүче ханым белән туганлык мөнәсәбәтендә булуы егетләргә шаяртукөлү өчен никадәр азык биргәнлеген күз алдына китерүе кыен түгелдер; тик Арамис Портосның тупас шаяртуына каршы ике-өч тапкыр кызарынып кына куйды да дусларына моннан ары бу темага әйләнеп кайтмаска кушты, шул турыда тагын бер генә сүз әйтсәгез дә, мондый йомыш белән тудыкамнан бүтән ярдәм сорамаячакмын, диде.

Шуңа күрә моннан ары инде безнең дүрт мушкетер сөйләшкән чакларында Мари Мишонны телгә алмадылар, ник дигәндә, алар теләкләренә ирештеләр инде: Бетюндагы кармелиткалар монастыреннан Бонасье ханымны алырга рөхсәт итә торган кәгазьне кулга төшерделәр. Дөрес анысы, Ларошель янындагы, икенче төрле итеп әйтсәк, Франциянең икенче башындагы лагерьда ятканда аларга ул рөхсәт кәгазенең файдасы бик аз иде. Шуңа күрә д'Артаньян үзенә ни өчен китәргә кирәклеген де Тревиль әфәндегә туп-туры әйтеп, ял сорарга дип җыенып йөргәндә генә де Тревиль әфәнде егеткә һәм аның өч иптәшенә корольнең егерме мушкетерлы сак белән Парижга кайтуын һәм егетләрнең шул сакчылар исәбенә кертелгәнлеген әйтте.

Дуслар моңа бик сөенештеләр. Хезмәтчеләрен багажлары белән алданрак җибәреп, үзләре иртәгесе көнне иртән юлга чыктылар.

Кардинал король хәзрәтләрен Сюржердан Мозега чаклы озата барды һәм шунда король белән аның министры бер-берсенә дуслык хисләрен белдереп саубуллаштылар.

Король, егерме өчесенә Парижга кайтып җитәргә ниятләп, мөмкин кадәр тизрәк хәрәкәт итәргә тырышты; шулай да күңел ачу өчен вакыт-вакыт ул кайчандыр герцог де Люинь мавыктырып җибәргән шөгыле — лачын сунарына да тукташтыргалады. Андый чакта егерме мушкетерның уналтысы болай күңелле итеп вакыт уздыруга бик сөенәләр, калган дүртесе исә, бигрәк тә д'Артаньян, бөтен дөньясын тетеп каргый, д'Артаньянның гел колаклары чыңлый иде. Колак чыңлавын Портос аңа болай дип аңлатты:

— Бер бик бай ханымның әйтүенә караганда, колак чыңласа, сине кайдадыр искә алып сөйлиләр, имеш,— диде.

Ниһаять, егерме өчесенә каршы төнне мушкетерлар сагы Париж аша узып, тиешле урынына барып җитте. Король, де Тревиль әфәндегә рәхмәт әйтеп, сакчыларны дүртәр көнгә ялга җибәрергә рөхсәт итте, тик ял итүчеләр, Бастилиягә эләгәселәре килмәсә, халык күп була торган төшләрдә күренеп йөрмәсеннәр, диде.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, иң беренче итеп безнең дүрт дуска ял бирделәр; алай гына да түгел әле, Атос де Тревиль әфәндедән дүрт көн урынына алты көн сорап алды, шуңа тагын ике төнне дә өстәде — алар ялга егерме дүртесе көнне кичке сәгать биштә киттеләр, де Тревиль әфәнде исә, бик риза булып, ялны егерме бишесеннән дип билгеләп куйды.

— Ай аллам, без юк кына нәрсәдән дә үзебезгә артык күп мәшәкать ясыйбыз, минемчә,— диде д'Артаньян; белгәнебезчә, аның икеләнә торган гадәте юк иде.— Ике көн эчендә мин икеөч ат яндырып (анысы миңа берни түгел, минем акчам бар!), Бетюнга барып җитәм, монастырь назирәсенә королеваның хатын тапшырам да сөйгәнемне Лотарингиягә дә, Бельгиягә дә илтмим, бәлки Парижга алып кайтам, анда аны яхшырак яшереп булачак, кардинал Ларошель янында торганда — бигрәк тә. Үзебез походтан әйләнеп кайткач инде королевадан — өлешчә аның тудыкасы ярдәменнән файдаланып, өлешчә үзебез кылган ярдәмнәребез өчен, ни теләсәк, шуны эшләтәбез. Сез монда гына калыгыз, бушка арып-талып йөрмәгез! Андый гына эш өчен Планше белән мин үзем дә бик җиткән.

Бу сүзгә каршы Атос тыныч кына болай дип җавап бирде:

— Анысы, акча бездә дә бар — йөзек сатканнан алган өлешемне мин эчеп бетермәдем әле, Портос белән Арамис та акчаларын ашап бетермәгәннәр. Димәк, без бер ат кына түгел, дүрт ат яндырып үтерә алабыз. Тик шуны исегездән чыгармагыз, д'Артаньян,— диде ул егетне сискәндереп җибәрерлек шомлы бер тавыш белән,— Бетюн ул — бөтен җирдә явызлык кылып йөрүче теге хатын белән кардинал күрешеп сөйләшкән шәһәр. Әгәр сез, д'Артаньян, дүрт ир белән генә эш итсәгез, мин сезнең үзегезне генә дә җибәрер идем. Сез әнә шул хатын белән эш итәчәксез, шуңа күрә анда дүртәү китәбез — ярый әле без дүртәү һәм тагын дүрт хезмәтчебез,— җитәрлек булсак!

— Сез мине өркетәсез, Атос! — диде д'Артаньян кычкыра төшеп.— И аллам, нәрсәсеннән куркасыз соң сез?

— Бөтенесеннән дә! — диде Атос.

Д'Артаньян игътибар беләнрәк иптәшләренә күз салды: Атос кебек, аларның да чырайларыннан зур борчуга төшкәнлекләре сизелеп тора иде; шуннан соң дүртесе дә, бер сүз сөйләшмәстән, атларын шпорлап юлларын дәвам иттерделәр.

Егерме бишесе көнне кичкырын Арраска килеп җиттеләр. Шунда д'Артаньян «Алтын тырма» кунакханәсендә берәр стакан шәраб эчеп чыгыйм дип атыннан төшкән чакта почта йортыннан бер җайдаклы чыкты да — бу кеше шунда атын алмаштырган иде — ял иткән чабышкысын кушаяклатып Парижга таба чаптырып китте.

Ул почта йорты капкасыннан урамга чыккан чагында аның,— август ае булуга карамастан,— өстенә бөркәнгән плащын җил ачып җибәрде, башыннан эшләпәсе дә очып китә язды, әмма сәфәрче эшләпәсен тотып алды да тиз генә күзләренә чаклы батырып киеп куйды.

Д'Артаньян, бу кешегә текәлеберәк карагач, көл төсле агарынып китте, кулыннан стаканын төшереп җибәрде.

— Ни булды сезгә, әфәндем? — дип шомланып сорады Планше.— Әй, әфәнделәр, тизрәк килегез әле,— хуҗа әфәндемнең кәефе начар!

Өч дус йөгерешеп килеп тә җиттеләр, ләкин д'Артаньянның һуштан язарга уенда да юк иде — ул тиз генә үзенең атына ташланды. Әмма аның юлына аркылы төштеләр.

— Кая ашкынасың бәреләсугыла, шайтан алгыры? — дип кычкырды Атос.

— Теге кеше! — дип кычкырды д'Артаньян.— Теге кеше! Җибәрегез мине, артыннан куып җитим әле.

— Кем соң ул? — дип сорады Атос.

— Шул инде, теге кеше!

— Нинди кеше?

— Теге каһәр суккан бәндә — миңа бер-бер бәхетсезлек килгән саен юлымда очрый торган газраилем! Теге яман хатынны беренче тапкыр күргән чагымда бу кеше аны озата бара иде. Аннары дустыбыз Атосны дуэльгә чакырган чагында мин шушы кешене эзләп чапкан идем, шуннан соң мин аны Бонасье ханым урланган көнне иртән күреп калган идем! Таныдым мин аны, шул үзе! Плащын җил ачып җибәргәч, танып калдым.

— Шайтан гына алсын! — дип уйга калып әйтеп куйды Атос.

— Атланыгыз, әфәнделәр, атланыгыз! Әйдәгез артыннан киттек, куып тотабыз без аны.

— Дустым, шуны онытмагыз,— диде Арамис аны тоткарлап,— ул без барасы юлның нәкъ кире ягына китте бит; аның аты да яхшы ял иткән, ә безнекеләр өшәнгән инде, шулай булгач, без аны куып тота алмыйбыз, атларыбызны гына яндырып

утерербез. Д'Артаньян, ир кешене ташлыйк та хатын-кызны коткарыйк без.

Шул вакыт капкадан бер ат караучы килеп чыкты һәм теге ят кеше артыннан ташланып:

— Әй, әфәндем! Әй, әфәндем! Эшләпәгездән кәгазегез төшеп калды! Әй, әфәндем! Әй! — дип кычкырды.

Д'Артаньян, аны туктатып:

— Дустым! Шул кәгазь өчен ярты пистоль акча аласың килмиме? — диде.

— Рәхим итегез, әфәндем, бик ризамын! Мәгез! — диде ат караучы һәм, бу табышына бик сөенеп, почта йортына кереп китте, д'Артаньян исә кәгазьне ачып, карарга керешге.

Дуслары, аның янына җыелышып:

— Нәрсә язылган? — дип сорадылар.

— Бер генә сүз язылган! — диде д'Артаньян.

— Шулай икән шул,— диде Арамис,— ләкин бу сүз берәр шәһәр яки авыл исеме булырга тиеш.

— «Армантьер»,— дип укыды Портос әлеге сүзне.— Армантьер... Андый җирне ишеткәнем юк.

— Бу шәһәр яки авыл исеме дигәнегез миледи кулы белән язылган бит! — дип куйды Атос.

— Алай булса, бу кәгазьне әйбәтләбрәк яшерик, бәлки, соңгы пистолемне чыгарып бирүем бушка түгелдер,— дип сүзгә нокта куйды д'Артаньян.— Әйдәгез, атларыбызга атландык, дуслар!

Шуннан инде безнең дүрт дус атларын юрттырып Бетюнга таба китеп бардылар.

## XXXI

## БЕТЮНДАГЫ КАРМЕЛИТКАЛАР МОНАСТЫРЕ

Зур җинаятьчеләргә тормыш юлларында үзенә бер төрле бәхет сыман нәрсә ияреп йөри. Ходай, алар кылган явызлыклардан тәмам туеп, ул җинаятьчеләрнең иркендә йөрүләренә чик куйганчы, алар шундый бәхет ярдәмендә бөтен каршылыкларны узалар, хәвеф-хәтәрләрдән котылалар.

Миледи белән дә шулай булды: ул ике дәүләтнең сакчы кораблары арасыннан тотылмыйча гына үтте дә, бернинди маҗараларга очрамыйча, Булоньга килеп җитте.

Портсмутка төшкән чагында миледи, милләтем белән мин инглизмен, французларның җәберсетүләре аркасында, Ларошельдән китәргә мәҗбүр булдым, дисә, ике көн буе диңгездә кайтып Булоньга килеп төшкәч, ул үзен Портсмутта Францияне дошман күрүче инглизләр тарафыннан эзәрлекләнгән бер француз хатыны итеп күрсәтте.

Шуның өстенә милединың иң ышанычлы паспорты: чибәрлеге, дәрәҗәле төс-кыяфәте һәм унга-сулга акча өләшә торган юмартлыгы да бар иде. Карт кына порт башлыгы үзен бик

әдәпле тоткан, ачык йөз күрсәткән булып аны гадәттәге рәсми тикшерүләрдән коткаргач, миледи Булоньда әллә ни озак юанмады, почта белән менә мондый хат җибәргәнче генә торды:

«Монсеньор кардинал хәзрәтләре де Ришельега, Ларошель янындагы лагерьга.

Галиҗәнап хәзрәтләре, тыныч булыгыз: герцог Бекингэм җәнаплары Франциягә килмәячәк.

Булонь, 25 августның киче.

Миледи ***

P. S. Сез галиҗәнап хәзрәтләренең теләгән истә тотып, Бетюнга, кармелиткалар монастырена китәм, шунда сезнең боерыкларыгызны көтәрмен».

Чыннан да, миледи шул кичне үк сәфәренә чыкты; юлда чагында төн җитеп, бер кунакханәгә кунарга туктады, иртәнге сәгать биштә инде тагын юлга чыгып, өч сәгатьтән соң Бетюнга килеп җитте.

Кармелиткалар монастыренең кайда икәнлеген сорашып белде дә туп-туры шунда китте.

Монастырь назирәсе аның каршысына чыкты; миледи аңа кардиналның боерыгын күрсәтте; аббатисса кунакны бүлмәгә урнаштырып, ашарына китерергә кушты.

Узгандагы күргән-кичергәннәре бу хатынның хәтереннән чыккан иде инде; ул, бөтен күңелен киләчәккә баглап, фәкать кардиналның зур рәхим-шәфкатьләрен генә көтә иде, чөнки ул кардиналга бик уңышлы хезмәт итеп, әлеге канлы эшкә аның исемен бөртек тә катнаштырмады.

Күңелен җилкетеп торган яңадан-яңа дәрт-тойгылары аның тормышын әле җете зәңгәрлекне, әле ут-ялкынны, әле давыл караңгысын чагылдырып күктә йөзгән һәм җир өстендә бары тик бәла-каза белән үлем эзләре генә калдырган болытлар сыман итте.

Иртәнге аш вакыты узганнан соң, аның янына визит белән аббатисса керде; монастырьда күңел юанырдай нәрсәләр бик аз иде, шуңа күрә яхшы күңелле назирәнең үз карамагына килгән яңа кеше белән тизрәк танышасы килә иде.

Миледи аббатиссага ошарга теләде; зирәк акыллы, сөйкемле-чибәр бу хатынга анысы әллә ни кыен эш түгел иде, әлбәттә; ул ачык чырайлы, сөйкемле-ягымлы булырга тырышты һәм кызыклы итеп сөйләшә белүе, бөтен килеш-кыяфәтендәге матурлыгы-нәзакәтлелеге белән яхшы күңелле назирәне тәмам үзенә гашыйк итте.

Аббатисса, бай нәселдән чыккан бер ханым булып, король сарае тирәсендәге төрле хәлләрне белергә бик ярата, чөнки андый хәлләр король дәүләтенең бу кадәр ерак төбәгенә бик сирәк килеп ишетелә, фани дөньядан аерылып яшәгән монастырьлар эченә исә тагы да сирәгрәк үтеп керә иде.

Ә милединың аксөякләр арасындагы интригалардан мәгълүматы бик зур иде, чөнки ул биш-алты ел буе гел шулар ара-

сында яшәде; шуңа күрә миледи яхшы күңелле аббатиссага француз короле сараендагы, корольнең чамадан артык диндарлыгы белән ярашып яшәгән җилбәзәклекләр турында сөйли башлады; миледи аны исемнәре аббатиссага яхшы ук таныш ханым һәм вельможаларның бөтен кешегә фаш булган гыйшык мажаралары белән таныштырды, королева белән Бекингэм арасындагы мәхәббәткә дә кагылып китте һәм, әңгәмәдәшенең дә теле чишелсен дип, тагы әлләниләр сөйләп бетерде.

Мәгәр аббатисса аның сөйләвенә җавап итеп бер сүз дә әйтмәде, бары тик елмаеп тыңлап кына утырды. Шулай да мондый әңгәмәнең назирәгә бик ошаганлыгын күреп, миледи шул ук рухта дәвам итте, тик сүзне хәзер кардиналга күчерде.

Ләкин зур аптырашта калды: миледи аббатиссаның роялисткамы, әллә кардиналисткамы икәнен белми иде, шуңа күрә ул саклык йөзеннән урталыктанрак барырга тырышты; аббатисса исә үзен тагын да саграк тота башлады, яңа килгән ханым кардинал хәзрәтләренең исемен телгә алган саен, монастырь назирәсе башын гына ия төште.

Милединың күңеленә: «Монастырьда миңа бик күңелсез булыр ахры» дигән уй килә башлады, шуңа күрә ул алга таба үзен ничегрәк тотарга кирәклеген хәзер үк ачыклау өчен тәвәккәл бер адым ясарга карар итте. Яхшы күңелле аббатиссаның тыйнаклыгы ни чамага кадәр җитәр икәнлеген белергә теләп, миледи башта читләтеп-читләтеп кенә, аннары инде ачыграк итеп кардиналны яманларга, министрның д'Эгильон, Марион Делорм ханымнар һәм җиңел генә кулга төшә торган башка хатыннар белән йөрүен сөйләргә кереште.

Аббатисса тагы да кызыксынырак тыңлый башлады, җанлана төште, елмая башлады.

«Яхшы, мин сөйләгәннәрнең тәмен сизә башлады бугай. Кардиналистка булган тәкъдирдә дә ул кадәр фанатизмы сизелми»,— дип уйлады миледи.

Аннан соң инде кардиналның дошманнарын эзәрлекләве турында сөйләп китте. Аббатисса монысында, хуплавын да, хупламавын да белгертмәстән, чукынгалап кына алды.

Моны күреп, миледи «монах ханым кардиналистка булудан бигрәк — роялисткадыр» дигән нәтиҗәгә килде.

Һәм буяуларны тагы да куерта төшеп сөйләвендә дәвам итте.

— Мин мондый нәрсәләрне бер дә белмим шул,— диде ниһаять аббатисса,— шулай да король сараеннан никадәр ерак яшәсәк тә, фани дөнья хәлләреннән никадәр аерылган булсак та, сез сөйләгәннәрнең кызганыч мисаллары бездә дә бар; безнең карамактагы бер хатын кардиналдан бик күп җәбер күргән — кардинал үчлек белән аны гел эзәрлекләп килгән.

— Сезнең карамактагы бер хатын,— дип кабатлады миледи аның сүзен.— И аллам! Бичара хатын, бик кызганыч.

— Сүзегез хак: бик кызганыч шул. Ниләр генә кичермәгән, бичара: төрмәгә дә утыртканнар, куркытканнар-өркеткәннәр дә, шәфкатьсез мөнәсәбәт тә күрсәткәннәр. Хәер, кардинал хәзрәт-

ләренең, бәлки, алай итәргә нигезле сәбәбе булгандыр,— диде аннары аббатиса,— болай карагаңда фәрештә булып күренсә дә, кешенең кыяфәтенә карап кына хөкем йөртеп булмый бит.

«Яхшы бу! Белмәссең, бәлки, мин монда берәр нәрсә ачыкларм.ын, миңа бик җайлы килеп тора бит әле!» — дип уйлады миледи.

Чыраена гадел бер төс чыгарырга тырышып:

— Шулай шул! Мин аны беләм инде. Кешенең чыраена бер дә ышанма, дип әйтәләр бит. Тәңре үзе яраткан шундый гүзәл нәрсәгә дә ышанмагач, тагын нигә ышанырга инде?! Мин, ихтимал, гомерем буе алданып яшәсәм дә, йөзе сөйкемле булып тоелган кешегә һәрвакыт ышанам,— диде.

— Димәк, сезнеңчә, ул яшь хатынның бернинди гаебе юк? — дип сорады аббатисса.

— Кардинал җәнаплары кешене бары тик җинаять кылганы өчен генә эзәрлекләми бит,— диде миледи,— кешенең кайбер яхшы сыйфатлары өчен дә явызлыктан да катырак эзәрлекли ул.

— Ханым, гаҗәпләнүемне белдерергә рөхсәт итегез,— диде аббатисса.

— Нәрсәгә гаҗәпләнүегезне? — дип самими бер төс белән сорады миледи

— Шундый сүзләр сөйләвегезгә.

— Минем бу сүзләремнең нәрсәсе гаҗәп? — дип елмаеп сорады миледи.

— Кардинал үзе сезне монда җибәргән икән, димәк, ул сезнең дустыгыз, ә сез...

— Ә мин аны яманлыйм,— диде миледи, монастырь назирәсенең сүзен дәвам иттереп.

— Һәрхәлдә, аның турында бер яхшы сүз дә сөйләмисез сез.

— Чөнки мин аның дусты түгел,— корбаны,— диде миледи көрсенеп.

— Ә анын сезне минем карамакка алырга дип әйтеп язган хаты?

— Берәр ярдәмчесенә мине моннан чыгарырга дип кушканчы, аның ул хаты миңа монда төрмәдәге кебек яту өчен боерык булып торачак.

— Алайса нигә качмадыгыз?

— Кая качыйм? Кардинал теләсә, дөньяда аның кулы җитмәслек урын бар дип уйлыйсызмы әллә? Әгәр ир кеше булсам икән, ул чагында качып булыр иде әле, ә хатын-кызга... Хатын-кыз нишли ала ул?.. Ә бу, сездә яши торган хатын качарга тырышып караганмыни?

— Юк, карамаган. Аныкы башка. Минемчә, ул кемнедер сөйгәнгә күрә Франциядән китә алмый.

— Сөйгән кешесе булгач, бөтенләй үк бәхетсез хатын түгел икән әле,— диде миледи көрсенеп.

— Димәк, минем каршымда җәбер-каһәр күрүче тагын бер хатын утыра,— диде аббатисса, тагы да кызыксына төшеп миледига күзен төбәде.

— Әйе шул! — диде миледи.

Аббатиссаның күңелендә яңа бер уй туган кебек, күзләрендә борчылу галәмәтләре чагылып китте.

Тотлыга-тотлыга гына:

— Сез безнең изге динебезнең дошманы түгелме? — дип сорады.

— Мин? — дип кычкырып җибәрде миледи.— Мин — протестант?! Юк, менә үзебезне күреп-ишетеп торган ходай шаһит: киресенчә, мин чын католикмын.

— Алайса, тыныч булыгыз, ханым,— диде аббатисса елмаеп,— бу йорт сезнең өчен ягымсыз бер төрмә булмас, тоткынлыкта ятуыгызны үзегезгә ошарлык итәргә тырышырбыз. Алай гына да түгел, әлеге, сарайдагы ниндидер интрига аркасында каһәргә эләккән яшь хатынны да күрерсез.

—Ни исемле ул?

— Бик зур бер олуг ханым аны минем карамакка тапшырганда Кэтти исемле дигән иде. Минем аның чын исемен белергә тырышып караганым юк әле.

— Кэтти! — дип кычкырып куйды миледи.— Ничек ул, тәгаен шулаймы?..

— Ул хатынның исемен әйтәсезме? Әйе, шулай, ханым. Әллә сез аны беләсезме?

Миледи эченнән генә көлеп куйды. «Ул минем теге камеристкам түгел микән?» дигән уй килде күңеленә. Шул яшь кызны хәтерләгәч, милединың аннан үч аласы исенә төште һәм зәһәр ачудан чырае бозылып китте; хәер, чыраен йөз төрле итә белә торган бу хатын шундук яңадан ягымлы, сабыр төсенә кайтты.

— Мин ул яшь ханымны кайчан күрә алырмын икән соң? Мин аны ярата да башладым бугай инде,— диде миледи.

— Бүген кич,— диде аббатисса,— теләсәгез, көндез үк тә күрә аласыз. Әйтүегезгә караганда, сез бит дүрт көн буе юл килгәнсез, бүген иртән сәгать биштә үк йокыдан торгансыз, сезнең, мөгаен, ял итәсегез киләдер. Ятып бераз йоклап алыгыз, төш алдыннан уятырбыз.

Күңелен җилкетеп, йөрәген кыҗратып күз алдында яңа бер мәкерле эш торганда миледига йокламый калса да берни булмас иде, шулай да ул монастырь назирәсенең киңәшен тотасы итте: соңгы атна эчендә миледи байтак хәлләр кичерде шул, аның тимер кебек таза гәүдәсе ару-талуга бирешмәсә дә, җаны тынгылык сорый иде.

Шуннан инде ул аббатисса белән саубуллашты да, Кэтти исемен ишеткәч күңелендә кузгалган үч тойгылары ләззәтенә бирелеп, йокларга ятты. Керешкән эшен миледи уңышлы башкарып чыкса, кардиналның аңа бернинди чикләүсез диярлек үзе теләгәнчә эш итәргә ирек бирәм дигән вәгъдәсен исенә төшерде. Миледи инде керешкән эшен уңышлы башкарып чыкты, шулай булгач, д'Артаньян хәзер аның хөкемендә, димәк.

Тик бер нәрсә — ире граф де ла Фер гына милединың исенә төшкән саен котын ала иде. Ул бит аны үлгәндер я булмаса

Францияне ташлап башка бер җиргә киткәндер дип уйлаган иде, бактың исә, д'Артаньянның иң якын дусты Атос аның шул ире булып чыкты.

Атос д'Артаньянның дусты булгач, королеваның кардинал хәзрәтләренең ниятен җимергән астыртын эшләрендә ул д'Артаньянга ярдәм иткәндер; Атос д'Артаньянның дусты икән, димәк, ул кардиналның дошманы; миледи, билгеле, үзе корган үч җәтмәсенә аны барыбер китереп кертәчәк һәм шул җәтмәдә, әлбәттә, мушкетер егетне буып үтерәчәк.

Миледи әнә шулай уйлап күңелен юатты һәм озакламый тәмам тынычланып, йокыга талды.

Караваты янында гына яңгыраган ягымлы бер тавыш аны йокысыннан уятты. Миледи күзен ачып җибәрде — аның бүлмәсенә, аксыл-сары чәчле, матур нәфис йөзле бер яшь хатын ияртеп, аббатисса килеп кергән, ияреп кергән әлеге хатын бик кызыксынган дустанә төс белән аңа текәлеп карап тора иде.

Миледига бөтенләй таныш булмаган бер хатын иде бу. Икесе дә, гадәттәгечә исәнләшкәч, игътибар белән бер-берсенә күз йөртеп алдылар: алар икесе дә чибәр, тик икесе ике төрле чибәр иде. Шулай да миледи, эченнән генә елмаеп, бу яшь хатын белән чагыштырганда үзенең мәһабәтрәк һәм затлырак кыланышлы икәнлеген уйлап куйды. Дөрес анысы — яшь ханымның буена сыланып торган күлмәге болай ярышыр өчен бигүк отышлы түгел иде түгелен.

Аббатисса аларны үзара таныштырды да, монастырь назирәсе буларак чиркәүгә барасы булганлыктан, бүлмәдән чыгып китте, ике хатын үзләре генә калдылар.

Милединың урынында ята бирүен күреп, аббатисса артыннан яшь хатын да чыгып китмәкче булган иде дә миледи аны туктатып калды.

— Ничек инде алай, ханым,— диде миледи,— мин бит әле сезне күреп тә өлгермәдем — сез инде мине ялгызым калдырып чыгып та китәсез: ихластыр, монда яшәгән чагымда мин сезнең белән күрешеп сөйләшкәләрмен диебрәк тә исәпләгән идем.

— Алай түгел, ханым,— диде яшь хатын,— вакытсызрак килгәнмен дип кенә курыктым мин: сез бит әле йоклап ята идегез, сез бик арыгансыздыр...

— Йокласа ни?! — диде миледи бу сүзгә каршы.— Йоклап ятучының теләге нәрсә? Күңеллелек тоеп уяну! Сез мине нәкъ шулай уяттыгыз, шулай булгач, сез мине ул күңеллелектән мәхрүм итмәгез инде.

Шуннан миледи яшь хатынны кулыннан тотып, караваты янындагы креслога таба тартты.

Хатын креслога утырды.

— И аллам, мин бәхетсезгә гел вакытсыз инде! — диде ул.— Минем монда яши башлаганыма ярты ел инде, күңел ачардай бер нәрсә юк; хәзер менә сез килдегез, сезнең белән күрешкәләү минем өчен бик күңелле булыр кебек тә, тик менә шушы арада монастырьдан чыгып китәрмен ахры!

— Ничек инде ул?! — диде миледи гаҗәпләнеп.— Озаклапмый монастырьдан китәсезмени сез?

— Һич югы, шулай дип өмет итәм,— диде яшь хатын, шатлыгын яшермичә.

— Минем беркадәр ишетүемчә, сез кардиналдан байтак кына каһәр күргәнсез бугай. Алай булганда безнең дуслыгыбыз өчен менә тагын бер сәбәп бар.

— Алайса, назирә анакай дөрес әйткән: минем кебек, сез дә ул явыз пастырьның бер корбанымы?

— Әкренрәк! — дип миледи яшь хатынны сүзеннән бүлде.— Хәтта монда да аның турында алай сөйләшмик. Минем бөтен бәхетсезлегем дустым дип санап йөргән бер хатын алдында менә хәзер сезнең кебегрәк әйтүем аркасында булды. Мине сатты ул. Сез дә шундый хыянәт корбанымы?

— Юк, мин үземнең тугрылыгымның, үзем бик яраткан бер хатынга тугры булуымның корбаны — ул хатын өчен мин гомеремне дә кызганмас идем.

— Шул хатын инде сезне бәлагә очрагач ташлап киттеме? Гадәттә һәрвакыт шулай була!

— Мин үзем дә шулай дип уйлаган идем дә бик нык ялгышканмын икән: моннан ике-өч көн элек кенә мин аның алай түгел икәнлегенә ышандым. Моның өчен ходайга рәхмәт укыйм: ул хатын мине онытты дигән уйда яшәү минем өчен бик зур газап булган булыр иде... Ә сез, ханым, сез ирекле бугай, теләсәгез качып та китә аласыз, анысы сезнең теләккә генә бәйле.

— Дусларым, акчам булмагач, мин кая бара алам, бер тапкыр да үзем булмаган чит-ят җирләрдә мин нишли алам?..

— Һай, дуслар дигәнен сез кая барсагыз да булдырырсыз! Сез шундый ягымлы, шундый чибәрсез бит! — диде яшь хатын.

— Ягымлы, чибәр булсам да, гел каһәр күреп ялгыз яшим,— диде миледи, елмаюына фәрештә төсләре бирергә тырышып.

— Ышаныгыз сүземә,— дип кереште яшь хатын,— ходайның рәхим-шәфкатенә өмет тотып яшәргә кирәк: бер тапкыр кылган яхшылыгыбыз һәрвакыт ходай каршында үзебез өчен яхшылык булып әйләнеп кайта. Мин никадәр көчсез, бичара бер хатын булсам да, мине очратуыгыз, бәлки, сезнең өчен бер бәхеттер. Моннан котылсам, мин зур дәрәҗәле дусларым аркасында котылам, миңа ярдәм иткәч, алар сезгә дә ярдәм итә алырлар.

— Үземне ялгыз дигәч тә, минем зур дәрәҗәле дусларым юк дигән сүз түгел ул,— диде миледи, шулай үзе турында сөйләп ул яшь хатынны ихлас күңелдән сөйләндерә алырмын дип өметләнде.— Тик ул танышларым кардинал каршында үзләре дә кан калтырап торалар шул, королева үзе дә дәһшәтле министрга каршы барып берәүне дә якларга батырчылык итми; королеваның, бик мәрхәмәтле булса да, үзенә ярдәм иткән кешеләрне кардинал хәзрәтләренең каһәренә корбан итәргә мәҗбүр булганлыгына дәлилләрем бар минем.

— Ышаныгыз, ханым, королеваның ул кешеләрдән йөз чөергән булып күренүе дә ихтимал, әмма алай тоелганга карап кына хөкем чыгарырга ярамый бит: ул кешеләр никадәр катырак кайгырлансалар, алар турында королева шулкадәр күбрәк уйлый, һәм еш кына, королеваның инде ярдәмен көтмәгән чакларында, шәфкатьле олуг ханым үзләрен онытмаганлыгын күреп ышаналар.

— Һай, шулай булсачы! — диде миледи көрсенеп.— Моңа мин ышанам, королева бик мәрхәмәтле ханым бит.

— Аһ, олы җанлы, гүзәл королевабыз турында шундый сүзләр әйткәч, димәк, сез аны беләсез? — диде яшь ханым әсәрләнә төшеп.

Миледи арттырыбрак җибәргәнлеген абайлап алды:

— Минем аның үзе белән турыдан-туры танышлыгым юк, мин аның якын дусларыннан байтагысы белән таныш димәкче идем; мин де Пютанж әфәндене беләм, Англиядән Дюжар әфәнде таныш, де Тревиль әфәндене беләм,— диде.

— Де Тревиль әфәндене беләсез?! — дип кычкырып җибәрде яшь хатын.— Де Тревиль әфәнде белән танышмыни сез?

— Таныш шул, яхшы ук танышмын.

— Король мушкетерлары капитаны беләнме?

— Әйе, король мушкетерлары капитаны белән.

— Алайса, менә күрерсез: без бик тиз якын танышлар, дуслар ук булып китәрбез! Де Тревиль әфәнде белән таныш булгач, сез инде аның өендә дә булгалагансыздыр?

— Әйе, бик еш булгалый идем! — диде миледи. Шундый юлга басып, ялганы оста чыгуын күргәч, ул ахырга чаклы шулай дәвам иттерергә булды.

— Сез анда кайбер мушкетерларны да очраткалагансыздыр инде?

Миледи, бу әңгәмә белән чын-чыннан кызыксынып китеп:

— Йортына килеп йөрүче бөтен мушкетерларны да очратканым бар,— дип җавап бирде.

— Белгәннәрегездән берәрсенең исемен әйтегез әле,— менә күрерсез: алар минем дус булып чыгар.

— Әйтик, мәсәлән...— дип тотлыгыбрак башлады миледи,— де Сувиньи әфәндене, де Куртиврон әфәндене, де Ферюссак әфәндене беләм.

Яшь ханым миледины сүзеннән бүлдермичә тыңлап торды, аннары инде, миледи сүзен әйтеп бетергәч, ул:

— Атос исемле бер кавалерны белмисезме? — дип сорады.

Миледи үзе җәеп яткан киндер җәймәсе төсле агарынып китте һәм үзен никадәр кулда тота белсә дә, ирексездән кычкырып куеп, әңгәмәдәшен күзләре белән ашардай булып, кулыннан тотып алды.

— Нәрсә бар? Ни булды сезгә? — диде бичара хатын.— Ай аллам, әллә сезне кимсетә торган берәр сүз әйттемме?

— Юк ла, шул исемне ишеткәч гаҗәпкә калдым, чөнки ул

кавалерны мин дә беләм, аның белән яхшы ук таныш кешене очратуым бик гаҗәп тоелып китте.

— Әйе, яхшы ук танышмын, бик яхшы таныш! Ул гына да түгел, аның дуслары Портос һәм Арамис әфәнделәр белән дә танышмын.

— Чынлапмы? Аларны мин дә беләм! — диде миледи, куркуыннан йөрәгә өши башлаганын тоеп.

— Алай таныш булгач, сез, әлбәттә, аларның батыр йөрәкле бик шәп егетләр икәнен дә беләсездер. Үзегезгә ярдәм кирәк булгач, нигә сез шуларга гына мөрәҗәгать итмисез соң?

— Хикмәт шунда...— дип тотлыга-тотлыга аңлатырга керешге миледи,— аларның берсе белән дә минем дуслык бәйләнешым юк. Мин аларны дуслары д'Артаньян әфәндедән сөйләве буенча гына беләм шул.

Яшь ханым да үз нәүбәтендә милединың кулыннан тотып алып, күзләрен аңа текәгән килеш:

— Сез д'Артаньян әфәндене беләсезмени?! — дип кычкырып әйтеп куйды. Аннары милединың сәер күз карашын күреп: — Гафу итегез, ханым, сез аның белән нинди рәк мөнәсәбәттә соң? — дип сорады.

— Ул... ул минем дустым,— диде миледи уңайсызланып.

— Алдашасыз, ханым, сез аның сөяркәсе булгансыз! — диде яшь хатын.

— Сез үзегез д'Артаньянның сөяркәсе булгансыз! — диде миледи бу сүзгә каршы.

— Минме?! — диде яшь ханым.

— Әйе, сез. Мин сезне хәзер белдем: сез Бонасье ханым.

Яшь хатын бик гаҗәпсенеп һәм куркынып артка чигенде.

— Яшереп маташмагыз! Җавап бирегез! — диде миледи.

— Ярый алайса! Әйе, шулай, ханым! Димәк, без көндәшләр? — диде яшь хатын.

Милединың йөзе зәһәр бер ачудан шундый кызарынып-бозарынып китте — башка бер очрак булса, Бонасье ханым куркуыннан кача ук башлар иде, тик бу юлы аны көнчелеге тотып калды.

Моңарчы һич сизелмәгән бер үҗәтлек белән ул:

— Яшерми генә әйтегез әле, ханым, сез элегрәк аның сөяркәсе идегезме, әллә хәзерме? — дип сорады.

Миледи исә бернинди шик калдырмаслык тавыш белән әйтте:

— Һич юк! Беркайчан да аның сөяркәсе булганым юк минем! — диде.

— Мин сезнең сүзегезгә ышанам, тик, алайса, ни сәбәптән сез шулай кычкырып җибәрдегез соң? — диде Бонасье ханым.

Милединың инде каушавы беткән, ул үз-үзен кулга алып өлгергән иде, шуңа күрә ул гаҗәпләнгән-сәерсенгән булып кына:

— Ничек инде, шуны да төшенмисезме? — дигән булды.

— Ничек төшеним? Мин бит берни белмим.

— Д'Артаньян әфәнденең миңа дусты итеп йөрәк серләрен сөйләгәнлеген төшенмисезме?

— Чынлапмы?

— Әйе, миңа бөтенесе дә билгеле: Сен-Клудагы бер йорттан сезне урлап китүләре дә, д'Артаньян әфәнде белән дусларының аһ-уһ килүләре дә, аларның сезне эзләп азаплануларыда! Шулай булгач, бер дә көтмәгәндә сезне очраткач, ничек гаҗәпләнмим ди инде мин! Без бит сезнең хакта бик еш сөйләшә идек, сезне ул бөтен җаны-тәне белән сөя, мин дә, танышмас борын ук, сезне яраттым! Һай, Констанция кадерлем, ахыр чиктә сезне таптым бит мин, сезне күрү бәхетенә ирештем бит!..

Шулай дип, миледи Бонасье ханымга кулын сузды, Бонасье ханым исә, аның әйткәннәренә ышанып, әлерәк кенә көндәше итеп санаган бу хатынны хәзер үзенең турылыклы, ихлас күңелле бер дусты итеп күрә башлады.

— Ай, гафу итегез инде мине! Гафу итегез! — диде яшь ханым.— Бик яратам шул мин аны! — дип, милединың җилкәсенә башын салды.

Ике хатын әнә шулай беравык кочаклашып тордылар. Әгәр шунда милединың көч-куәте нәфрәтенә бәрабәр булса, әлбәттә, Бонасье ханымны кочагыннан исән килеш ычкындырмаган булыр иде. Әмма яшь ханымны буып үтерерлек көче булмагач, миледи аңа елмаеп кына әйтте:

— Матурым-чибәрем, кадерле сеңелкәшем! Сезне болай очратып күрүемә шундый да шатмын! Кая, үзегезне туйганчы бер күрим әле!

Миледи үзе шулай дип сөйләнә, үзе аны күзләре белән ашардай булып карый иде.

— Әйе, әйе, әлбәттә, ул хатын — сез. Д'Артаньян әфәнде сөйләгәннәр буенча таныйм мин сезне, бик яхшы таныйм.

Бичара яшь ханым чиста ак маңгайлы, җем-җем иткән зәңгәр күзле бу хатынның күңелендә явыз ниятләре барлыгын уена да китермәде, миледи аны кызгана, якын итә кебек кенә тоелды.

— Ул сезгә үзенең кичерешләрен сөйләгәч, димәк, минем ниләр кичергәнем сезгә мәгълүм инде... Әмма аның хакына газап кичерү — үзе бер бәхет! — диде Бонасье ханым.

Миледи, аның сүзенә ияреп:

— Әйе, бәхет,— дип куйды, күңеле исә башка нәрсә уйлады.

— Өстәвенә минем болай газап чигеп йөрүләрем озакламый бетәчәк инде,— дип сөйләнүендә дәвам итте Бонасье ханым,— иртәгә, бәлки әле бүген кич белән үк, мин аны яңадан күрәчәкмен, шуннан соң инде бу ямансулыклар онытылыр.

— Бүген кич белән? Иртәгә? — дип кайтарып сорады миледи: бу сүзләрне ишеткәч, уйларыннан айнып китте — Моның белән ни димәкче буласыз? Аңардан берәр төрле хәбәр көтәсезме әллә?

— Мин аның үзен көтәм.

— Үзен?! Д'Артаньян бирегә киләмени?

— Әйе, килә.

— Алай булуы мөмкин түгел! Ул бит Ларошельне камаган төштә, кардинал белән бергә, каланы алганнан соң гына кайтачак.

— Шулай дип уйлыйсызмы? Минем д'Артаньяным өчен — шундый батыр йөрәкле кавалер өчен — дөньяда мөмкин булмаган эш бармыни ул?!

— Сезнең сүзегезгә ышана алмыйм!

Шатлык-куанычы эченә сыймаган бичара хатын:

— Алайса, менә мәгез, үзегез укып карагыз! — диде дә миледига хат чыгарып бирде.

«Де Шеврез ханым кулы,— дип күңеленнән уйлап куйды миледи.— Мин аларны ул лагерь белән бәйләнеш тоталар дип уйлаган идем шул, дөрес икән!»

Шуннан соң ул йотылып дигәндәй мондый юлларны күзеннән кичерде:

«Балакаем, әзер булып торыгыз. Озакламый *дустыбыз* сезнең янга килеп чыгачак, сезне исәнлек-иминлегегез өчен кереп сыенган җирдән — төрмәдән коткарырга киләчәк. Кайтып китәргә әзер булып торыгыз, безнең ярдәмнән беркайчан да өмет өзмәгез.

Безнең сөйкемле Гасконь егете шушы арада гына үзен һәрвакыттагыча безгә тугрылыклы, батыр кеше итеп күрсәтте; берәүләрнең аңа алдан искәртеп куйганы өчен бик зур рәхмәт укуларын әйтегез».

— Шулай икән, шулай икән, хатта ап-ачык әйтелгән. Искәрт дигәннәренең нәрсә хакында икәнлеген белмисезме? — диде миледи.

— Юк, белмим шул. Шулай да королеваны кардиналның яңа әшәкелекләр эшләргә җыенуы хакында искәртеп куймады микән дип уйлыйм.

Миледи:

— Мөгаен, шулайдыр,— дип, хатны Бонасье ханымга кире кайтарды да уйга калып яңадан башын аска иде.

Шул вакытны дөп-дөп итеп ат чабып килгәне ишетелде.

Бонасье ханым:

— Аһ! Ул түгелме бу? — диде дә тәрәзәгә ташланды.

Миледи, гаҗәпләнүдән таш кебек катып, караватында ята калды, бу кадәр көтелмәгән хәлләрдән ул гомерендә беренче тапкыр каушап-югалып калды.

— Ул! Ул! — дип пышылдап сөйләнде.— Ул микән соң? — диде.

Хәрәкәтсез катып калган күзләрен бушлыкка төбәп, караватында ята бирде.

— Аһ, ул түгел икән лә! — диде Бонасье ханым, авыр сулап.— Мин белмәгән ниндидер бер кеше, шулай да безнең янга килүче бугай. Әйе, әнә атын тыя төште... капка төбенә килеп туктады... кыңгырауны чыңлата.

Миледи караватыннан сикереп торды.

— Сез аның ул түгеллегенә ышанып әйтәсезме? — дип сорады.

— Әйе, ышанып әйтәм!

— Бәлки, күреп җиткермәгәнсездер?

— Аһ, эшләпәсендәге каурыен, плащ очын гына күрсәм дә таныйм мин аны!

Миледи киенә бирде.

— Барыбер инде: ул кешене монда килә дисез түгелме соң?

— Әйе, керде инде.

— Я ул сезнең янга, я миңа килә.

— Ай аллам! Кыяфәтегез шундый борчулы!

— Әйе, мин сезнең кебек бик ышанучан кеше түгелмен шул, кардиналдан бик шикләнәм.

— Әкрен! — диде Бонасье ханым, аны сүзеннән туктатып.— Монда киләләр!

Чыннан да, ишек ачылып китеп, бүлмәгә монастырь назирәсе килеп керде.

— Булоньнан килүче сез буласызмы? — диде ул, миледига мөрәҗәгать итеп.

— Әйе, мин булам,— диде миледи, тынычрак булырга тырышып.— Кем сорый мине?

— Бер кеше: исемен әйтергә теләми, кардинал кушуы буенча килдем, ди.

— Мине күрергә телимени?

— Булоньнан килгән ханымны күрергә тели ул.

— Ул чагында, рәхим итсен, монда чакырыгыз аны, ханым.

— Ай аллам! Ай аллам! — диде Бонасье ханым, коты алынып.— Бер-бер яман хәбәр китерүче булмаса гына ярый инде!

— Үзем дә шулай булмагае дип куркам шул.

— Мин инде чыгып торыйм, ул ят кеше киту белән, рөхсәт итсәгез, тагын керермен.

— Әлбәттә, рәхим итегез.

Монастырь назирәсе белән Бонасье ханым чыгып киттеләр.

Миледи, ялгызы гына калып, күзен ишеккә төбәде; беравыктан бөтен баскычка чак-чок итеп шпор чыңлаганы ишетелде, аннары аяк тавышы якынаеп, ишек ачылды да бусагада бер кеше күренде.

Миледи сөенеченнән кычкырып җибәрде; аның янына килеп керүче кеше кардиналга җаны-тәне белән бирелгән граф де Рошфор иде.

## *XXXII*

## *ИКЕ ТӨР ИБЛИС*

Миледи белән Рошфор икесе берьюлы эндәштеләр:

— Ә! Сезмени бу!

— Әйе, мин.

— Каян килешегез?..— дип сорады миледи.

— Ларошель яныннан, ә сез?

— Англиядән.

— Бекингэм ничек?

— Үлгәндер, я бик каты яралангандыр; мин, бернигә ирешә алмыйча, китеп барган чакта бер фанатик үтергән аны.

— А! — дип, Рошфор көлеп куйды.— Менә монысына фарт килгән! Кардинал хәзрәтләре моңа бик сөенер инде. Сез аңа хәбәр иттегезме әле?

— Мин аңа Булоньнан хат язган идем. Ә сез ничек монда килеп чыктыгыз соң?

— Кардинал хәзрәтләре, борчылып, сезне эзләргә җибәрде мине.

— Мин әле кичә генә килеп җиттем.

— Кичәдән бирле нишләр эшләдегез соң?

— Вакытымны бушка уздырмадым.

— О! Анысына шикләнмим!

— Беләсезме, кемне очраттым мин монда?

— Белмим шул.

— Уйлап карагыз әле!

— Каян белим мин аны?..

— Королева төрмәдән азат иткән яшь ханымны.

— Теге д'Артаньян дигән малайның сөяркәсенме?

— Әйе, Бонасье ханымны; аның кайда икәнлеге кардиналга мәгълүм түгел иде бит әле.

— Менә, тагын бер фарт туры килгән, тегесе шикелле үк,— диде Рошфор.—Кардинал җәнапларына гел уңышлы килеп тора!

— Шул хатын белән йөзгә-йөз очрашкач, минем никадәр гаҗәпләнгәнемне белсәгез икән! — диде миледи.

— Ул сезне беләме соң?

— Юк.

— Димәк, сез аның өчен чит-ят кеше?

Миледи көлемсерәп куйды.

— Мин аның иң якын дусты.

— Ант әгәр, сөекле графиня, андый могҗизаларны бары тик сез генә булдыра аласыз!

— Минем аның белән дусланып китүем бик бәхеткә булды әле, кавалер: беләсезме, монда нинди хәлләр буласы?

— Белмим шул.

— Иртәгә, я берсекөнгә королева боерыгы белән әлеге ханымны алып китәргә киләчәкләр.

— Алай икән! Кемнәр килә соң?

— Д'Артаньян белән аның дуслары.

— Валлаһи, алар үзләрен тотып Бастилиягә утыртканны көтеп йөриләр.

— Нигә алар шушы көнгә хәтле иректә йөриләр соң әле?

— Берни эшләп тә булмый шул! Кардинал җәнаплары ни сәбәптәндер ул кешеләргә җылы караш күрсәтә.

— Чынлапмы?

— Чынлап.

— Алайса сез аңа, Рошфор, шулай дип әйтегез: безнең «Күгәрчен оясы»нда сөйләшкән сүзләрне әлеге дүрт кеше тыңлап торганнар; кардинал хәзрәтләре киткәннән соң, шуларның берсе минем янга килеп керде дә кардинал биргән рөхсәт кәгазен миннән талап алды; шуны да әйтегез: алар минем Англиягә китүем турында лорд Винтерга алдан әйтеп куйганнар; асылташлар белән булган кебек, алар бу юлы да кардинал хәзрәтләренең кушканын башкарып чыгарга комачаулый яздылар; тагын шунысын да әйтегез: ул дүрт кешенең икәве генә: д'Артаньян белән Атос кына куркыныч; өченчесе, Арамис дигәннәре — де Шеврез ханымның сөйгән егете: аңа тимәскә кирәк, безгә аның сере билгеле, аның безгә кирәк булуы ихтимал; дүртенчесенә, Портоска килгәндә исә, анысы бер җүләр, ахмак бер җилбәзәк, аңа игътибар итеп тә торасы юк.

— Алар хәзер дүртесе дә Ларошельне камауга катнашалардыр бит?

— Мин үзем дә шулай дип уйлаган идем дә, Бонасье ханым коннетабль хатыныннан алган хатны саксызлык белән миңа күрсәткәч, шул хаттан чыгып, мин, алар хәзер, киресенчә, дүртәүләп, Бонасье ханымны урлау өчен, монда кайталар дигән уйга килдем.

— Ах, шайтан алгыры! Нишләргә соң?

— Кардинал минем хакта нинди боерыклар бирде?

— Сездән — язмачамы, телдәнме — мәгълүматлар алып, почта атлары белән кире кайтырга кушты, сезнең ниләр эшләгәнегезне белгәннән соң инде сезгә киләчәктә нишләргә икәнлеген хәл итәчәк ул.

— Алайса мин монда калырга тиешме?

— Монда яки шушы тирәдә.

— Сез мине үзегез белән алып китә алмыйсызмы?

— Юк шул, миңа бик төгәл боерык бирелде,— лагерь тирәсендә сезне танып калулары ихтимал, ә сезнең анда булуыгыз, үзегез дә аңлыйсыздыр, кардинал хәзрәтләренә күләгә төшерүе мөмкин.

— Ярый алайса, миңа монда яки шушы тирәдә көтәргә туры килер.

— Тик сез миңа үзегезне кайдан табарга икәнлеген белеп тору өчен алдан ук әйтеп куегыз: кардиналдан аласы хәбәрләрне сез кайда көтәргә уйлыйсыз?

— Карагыз әле, мин монда кала алмам ахры.

— Нигә?

— Бирегә менә-менә хәзер үк минем дошманнарым килеп керү ихтималын оныттыгызмыни?

— Анысы дөрес. Ул чагында әлеге яшь ханым кардинал хәзрәтләре кулыннан ычкыныр бит?

— Юк, ычкынмас! — диде миледи, үзенә генә бер елмаю белән.— Минем аның иң якын дусты икәнемне онытасыз.

— Әйе, анысы да дөрес! Шулай итеп, мин кардиналга әлеге хатын турында...

— Бер дә борчылмасын дип әйтә аласыз.

— Шул гынамы?

— Аның ни икәнен аңлар ул.

— Ул аңлый. Ә миңа хәзер нишләргә?

— Хәзер үк кайтып китегез. Минемчә, сез кардиналга кайтып әйтәсе хәбәрләр өчен ашыгырга да ярый.

— Лильерга килеп кергән чакта коляскам ватылды.

— Бик шәп булган!

— Ничек алай бик шәп?

— Шулай, миңа сезнең коляскагыз кирәк.

— Ул чагында мин ничек кайтып китәм?

— Атка атланып. Җан-фәрманга куарсыз атыгызны.

— Сезгә алай дип сөйләве ансат ла! Ә миңа ат өстендә йөз сиксән лье юл чабып узу бик авырга киләчәк шул!

— Берни булмас.

— Ярый, шулай булсын. Ә аннары?

— Аннары шул: Лильер аша узганда миңа коляскагызны җибәрерсез, хезмәтчегезгә минем карамакка килергә дип әйтерсез.

— Яхшы.

— Сездә кардиналның берәр боерыгы да бар, билгеле?

— Миңа үз карамагымча эш итәргә рөхсәт биргән язма вәкаләт бар.

— Сез шуны монастырь назирәсенә күрсәтегез дә, бүген я иртәгә мине алырга кеше килә, миңа сезнең исемнән килгән кеше белән китәргә кушылган, диегез.

— Бик яхшы.

— Назирә белән сөйләшкәндә минем турыда кырысрак әйтергә дә онытмагыз.

— Анысы нигә тагын?

— Мин — кардиналның корбаны. Мин әлеге беркатлы Бонасьены үземә ышандырырга тиешмен.

— Дөрес! Ә хәзер, рәхим итеп, булган хәлләрнең бөтенесен әйтеп донесение языгыз.

— Мин битниләр булганын сезгә сөйләп бирдем инде; сезнең хәтерегез бик яхшы, мин әйткәннәрне кабатлап күрсәтегез, кәгазьнең югалуы ихтимал бит.

— Сүзегез хак. Сезне бу тирәдә бушка эзләп йөрмәс өчен үзегезне каян табарга икәнен әйтсәгез иде.

— Дөрес. Туктагыз әле...

— Сезгә карта кирәкмиме?

— О! Бу тирәләрне бик яхшы беләм мин.

— Беләсез! Ә сезнең монда кайчан булганыгыз бар иде соң?

— Мин бит монда тәрбияләнеп үстем.

— Шулаймыни?

— Күрәсез, кайда тәрбияләнеп үсүеңнең дә кайвакыт файдасы тиеп куя икән.

— Шулай итеп, сез мине кайда көтәсез була инде?..
— Чак кына уйларга бирегез... Менә кайда: Армантьерда.
— Нәрсә соң ул Армантьер?
— Лис елгасы буендагы кечерәк бер кала: мин елга аша чыгу белән чит дәүләт җирендә булачакмын.
— Бик яхшы! Тик сез куркыныч-мазар була калса гына елга аша кичәрсез.
— Әлбәттә.
— Әгәренки андый хәл була калса, мин сезнең кайда икәнегезне ничек белермен?
— Сезгә лакеегыз кирәк түгелме?
— Түгел..
— Ышанычлы кешеме ул?
— Бик ышанычлы. Сыналган кеше инде ул.
— Сез аны минем карамакка бирегез. Аны беркем белми, мин аны үзем киткән төштә калдырырмын да ул сезне минем янга алып килер.
— Димәк, сез мине Армантьерда көтәчәксез?
— Әйе, Армантьерда.
— Шул исемне бер кәгазь кисәгенә язып бирегез әле, юкса онытырмын дип куркам. Каланың исемендә тап төшерердәй бер нәрсә дә юктыр бит, шулаймы?
— Кем белгән!.. Ярый, булса булыр, мин үземнең яхшы исемемә күләгә төшерергә дә әзермен! — диде миледи, ризалашып, һәм кәгазь кисәгенә каланың исемен язып бирде.
— Яхшы,— диде Рошфор, миледи кулыннан кәгазьне алып бөкләде дә эшләпә эчлеге астына кыстырып куйды.— Хәер, бу кәгазьне югалткан тәкъдирдә дә бер дә борчылмагыз: мин, балалар шикелле, бу исемне юл буе кабатлап кайтачакмын. Шулай итеп, сөйләшеп беттек шикелле?
— Шулай бугай.
— Хәтергә ныгытыбрак салыйк әле: Бекингэмны үтерәләр яки яралыйлар... сезнең кардинал белән сөйләшкәнегезне дүрт мушкетер тыңлап торган... сезнең Портсмутка киләсегез турында лорд Винтерга әйтеп куйганнар... д'Артаньян белән Атосны Бастилиягә... Арамис — де Шеврез ханымның сөйгән егете... Портос — бер җилбәзәк... Бонасье ханым табылган... Сезгә тиз арада коляска җибәрергә... минем лакейны сезнең карамакка бирергә... монастырь назирәсенә бернинди шик тумасын өчен сезне кардиналның бер корбаны итеп күрсәтергә... Армантьер Лис елгасы буенда. Шулаймы?
— Валлаһи, хәтерегез искиткеч яхшы икән, хөрмәтле кавалер. Хәер, тагын берне өстисегез бар әле.
— Тагын нәрсә?
— Мин бик яхшы урман күрдем, монастырьның бакчасына килеп тоташа бугай ул. Монастырь назирәсенә әйтегез: миңа ул урманда йөрергә рөхсәт ителгән, диегез. Белеп булмый: бәлки миңа арткы ишектән чыгып китәргә туры килер.
— Сез аларын да кайгыртып куйгансыз икән инде!

— Сез тагын бер нәрсәне оныткансыз әле...

— Нәрсә ул?

— Миңа акча кирәкмиме? дип сорарга.

— Әйе, дөрес. Күпме бирим?

— Сездә күпме алтын бар — барысын да.

— Миндә бар булганы — биш йөз пистоль чамасы.

— Миндә дә шул чама. Мең пистоль акча белән теләсә нинди хәлдән чыгып була. Кесәгездә булганның барысын чыгарып салыгыз.

— Рәхим итәсез.

— Яхшы. Сез хәзер китәсезме инде?

— Бер сәгатьтән китәм. Бераз тамак ялгап аласым бар, ул арада берәрсе почта атын алып килер.

— Бик яхшы! Хушыгыз, кавалер!

— Хушыгыз, графиня!

— Кардиналга минем ихтирамымны тапшырыгыз.

— Ә сез иблискә минем ихтирамымны тапшырыгыз.

Миледи белән Рошфор бер-берсенә елмаешып аерылыштылар.

Бер сәгатьтән соң Рошфор атын кушаяклатып кире китеп барды; биш сәгать вакыттан соң ул Аррас аркылы узып китте.

Укучыларыбыз д'Артаньянның аны ничек таныганлыгын һәм бу очрашу дүрт мушкетерның күңелендә шик кузгатып, аларны ашыгыч рәвештә юлларын дәвам иттерергә мәҗбүр иткәнлеген беләләр инде.

## *XXXIII*

## *СОҢГЫ ТАМЧЫ*

Рошфор чыгып китү белән, бүлмәгә Бонасье ханым килеп керде һәм милединың шат елмаеп торганын күрде.

— Менә, куркып көткәнегез үтеп тә китте! — диде яшь ханым.— Бүген кич яки иртәгә кардинал безне алып китәргә кеше җибәрәчәк.

— Шулай дип сезгә кем әйтте, сабыем? — диде миледи.

— Атчабарның үз авызыннан ишеттем мин аны.

— Ягез, яныма килеп утырыгыз әле,— диде миледи.

— Рәхим итәсез.

— Туктагыз, безне берәрсе тыңлап тормый микән, карап килим әле.

— Нигә ул хәтле куркасыз?..

— Хәзер белерсез.

Миледи, торып, ишек катына барды, ишекне ачып, коридорга күз салды, аннары Бонасье ханым янына килеп утырды да:

— Димәк, ул үзенең ролен бик яхшы уйнады? — дип сорады.

— Кем?

— Монастырь назирәсенә үзен кардиналның йомышчысы итеп күрсәткән кеше.

— Роль генә уйнадымыни ул?

— Әйе, сеңлем.

— Димәк, ул кеше ни түгел...

— Ул кеше минем абыем,— диде миледи, әкренрәк тавыш белән.

— Абыегыз! — дип кычкыра төшеп әйтеп куйды Бонасье ханым.

— Минем бу серемне бары тик сез генә беләсез, сеңлем; әгәр аны берәр кешегә ачсагыз, минем башым бетәчәк, сезнең дә харап булуыгыз ихтимал.

— Ай аллам!

— Беләсезме, нәрсә булган: көч кулланып булса да мине азат итәргә дип ашыгып килгән чагында абыем кардиналның мине алып китәргә җибәргән атчабарын очрата да аның артыннан китә. Кешесез аулак бер урынга җиткәч, кылычын чыгара да атчабардан, бирмәсәң, үтерәм дип, аңардагы кәгазьләрне сорый; атчабар карышып маташкач, абыем аны кылычы белән кадап үтерә.

— Ah! — дип куйды Бонасье ханым коты очып.

— Беләсезме, аның шуннан башка чарасы булмаган! Шуннан инде абыем көч белән түгел, хәйлә белән эш итәргә уйлаган: тегеннән кәгазьләрне алган да монда кардиналның атчабары булып килгән, тагын бер-ике сәгатьтән инде кардиналның боерыгы буенча мине алырга карета килергә тиеш.

— Аңлыйм: ул каретаны сезгә абыегыз җибәрәдер.

— Нәкъ шулай. Тик моның белән генә бетми әле. Сез де Шеврез ханым язган дип уйлаган хат...

— Әйе?

— ...ялган хат ул.

— Ничек инде?

— Әйе, ялган хат: сезне алырга килгәч, сез карышмасын дип эшләнгән бер тозак кына ул.

— Мине алырга д'Артаньян килә ич.

— Саташмагыз: д'Артаньян белән аның дуслары Ларошельне камаган төштә хәзер.

— Ә сез аны каян беләсез?

— Абыем кардиналның мушкетер булып киенгән йомышчыларын очраткан. Сезне капка төбенә чакырып чыгарырлар да сез аларны дусларыгыз дип уйларсыз, аннары сезне урлап, кире Парижга алып китәрләр.

— Ай аллам!.. Бу хәтле башбаштаклыкта мин инде нишләргә дә белмим! Шушы хәлдә дәвам итсә, акылымнан язачакмын! — диде Бонасье ханым, учлары белән маңгаен тотып.

— Туктагыз әле!..

— Нәрсә бар?

— Ат чапкан тавыш ишетелә, абыем китеп бара бугай. Минем аның белән тагын бер тапкыр саубуллашасым килә, әйдәгез әле.

Миледи тәрәзәне ачып җибәрде дә кулын изәп кенә Бонасье ханымны чакырды. Яшь ханым аның янына килде.

Рошфор атын чаптырып тәрәзә турысыннан узып бара иде.

— Абый, сау бул!—дип кычкырды миледи.

Атта чабып барган кеше башын күтәреп ике яшь ханымга карады да миледига дусларча кул изәде.

Миледи, йөзенә сагышлы, назлы бер төс чыгарып:

— Бик әйбәт егет ул Жорж! — диде дә тәрәзәне япты.

Аннары, элекке урынына барып утыргач, шәхси уйларына чумган бер төскә керде.

— Уегыздан бүлдергәнем өчен гафу итегез, ханым! — диде аңа Бонасье ханым.— Миңа нишләргә киңәш итәсез соң сез? Ай аллам! Тормыш итү мәсьәләсендә сез миннән тәҗрибәлерәк, миңа нишләргә кирәклеген әйтегез әле.

— Иң элек, бәлки, мин ялгыша торганмындыр, д'Артаньян белән дуслары чыннан да сезгә ярдәмгә килеп чыгулары да ихтимал,— диде миледи.

— Һай, искиткеч булыр иде ул, аның булырына ышанып та җитмим! Андый бәхет миңа эләкмәс шул инде! — диде Бонасье ханым.

— Ул чагында инде, беләсезме, вакыт мәсьәләсенә генә кайтып кала ул, үзенә күрә бер ярыш — кем алданрак килеп җитә. Дусларыгыз элегрәк килсә — сез котыласыз, кардинал ялчылары килсә — харап буласыз.

— Һай! Шулай шул, беттем мин! Нишләргә соң инде, нишләргә?

— Аның бер чарасы бар бугай — бик гади, бик табигый чара.

— Нинди чара ул, әйтегез әле?

— Шушы якын тирәдә качып торып, башта сезне алырга килүче кешеләрнең кем икәнлеген белү.

— Ә кайда качып торырга соң?

— Анысын гына уйлап табарга була. Мин үзем моннан берничә льеда гына туктап, абыемның килгәнен көтеп торачакмын. Болай итәбез: мин сезне үзем белән алып китәм дә шунда качып икәү көтәбез.

— Мине моннан чыгармаслар шул, мин бит монда тоткын хәлендә.

— Мондагылар мине кардинал боерыгы белән китә дип беләләр, мине озата чыгарга тиеш түгелләр дип уйлыйлар.

— Шуннан?

— Шуннан шул: мине алырга карета килә, сез минем белән саубуллаша башлыйсыз, мине соңгы тапкыр кочакламакчы булып карета күтәрмәсенә менеп басасыз, абыемның мине алырга килгән хезмәтчесенә барысы да алдан әйтеп куелган була, почтачыга ул баш кына кага да җан-фәрманга чаптырып китеп барабыз.

— Әгәр д'Артаньян килеп чыкса?

— Анысын белербез.

— Ничек итеп?

— Һи, бик ансат ул. Абыемның хезмәтчесен кире Бетюнга

җибәрәбез,— кабатлап әйтәм: ышанычлы кеше ул. Өс-башын алмашып киенә дә монастырь каршына килеп урнаша: әгәр кардинал кешеләре килсә, урыныннан кузгалмый, д'Артаньян белән аның дуслары булса, аларны безнең янга алып килә.

— Ә ул аларны беләмени?

— Әлбәттә, белә, д'Артаньянны минем йортымда берничә тапкыр күргәне бар аның!

— Шулай шул, дөрес әйтәсез... Алайса эш бик әйбәт җайлана, шулай да моннан әллә ни ерак китмәбез.

— Иң күбе — җиде-сигез лье. Чик буендагы аулак бер урынга урнашырбыз да, куркыныч була калса, Франциядән китәрбез.

— Ә аңарчы нишлибез?

— Көтәбез.

— Әгәр алар килеп чыкса?

— Абыемның каретасы алданрак киләчәк.

— Сезне алырга килеп тә, мин сезнең янда булмасам: мәсәлән, минем ашаган чагым булса?

— Бер нәрсә эшләгез.

— Нинди нәрсә?

— Мәрхәмәтле назирәгә әйтегез: үзегезгә минем белән бергә ашарга рөхсәт сорагыз — безгә гел бергәрәк булырга кирәк.

— Рөхсәт итәр микән соң?

— Рөхсәт итмәслек бернәрсәсе дә юк ич аның.

— Бик яхшы! Димәк, без бер минутка да аерылып тормаячакбыз.

— Янына барыгыз да рөхсәт сорагыз! Ни сәбәптәндер минем башым авыраеп тора, бакчага чыгып йөреп керәм әле.

— Барыгыз, ә мин сезне кайдан табармын соң?

— Берәр сәгатьтән шушында булырмын.

— Берәр сәгатьтән шушында буласыз... Сез шундый яхшы кеше, бик рәхмәт инде сезгә!

— Ничек инде мин сезгә ярдәм итмим ди? Әгәр сез бу кадәр чибәр, сөйкемле хатын булмасагыз да ярдәм итәр идем мин, сез бит иң яхшы бер дустымның сөйгән яры.

— Һай, д'Артаньян җаным, сезгә бик рәхмәт укыр инде ул!

— Үзем дә шулай дип уйлыйм. Димәк, барысын да сөйләштек, әйдәгез, аска төшәбез.

— Сез бакчага чыгасызмы?

— Әйе.

— Менә бу коридордан китеп, кечкенә баскычтан төшегез, шуннан туп-туры бакчага килеп чыгарсыз.

— Бик яхшы! Рәхмәт.

Ике яшь хатын бер-берсенә елмаешып алдылар да үз юллары белән китеп бардылар.

Миледи, башым авыраеп тора, дип алдашмады, дөресен әйтте: аның башында чуалган уйларын рәткә китерәсе, очына чыгасы бар иде. Моның өчен аңа аулакта калырга кирәк иде. Ул алда булачак хәлләрне күз алдына әле ачык китереп бетерә

алмый, ачыкланып җитмәгән ниятен билгеле бер рәвешкә китерү, нишләргә кирәклегенең планын төзү өчен тынычлык кирәк иде аңа.

Иң элек тизрәк Бонасье ханымны урлап аны ышанычлы бер җиргә урнаштырырга, кирәк була калса, аны тоткын итеп тотарга кирәк иде. Миледи бу аяусыз көрәшнең нәтиҗәсен уйлап курка да башлады — бу көрәштә аның дошманнары никадәр тырышлык куйсалар, миледи да шул кадәр үк кару белән көч сала иде.

Өстәвенә ул, кайбер кешеләр яшенләп яңгыр явасын алдан сизгән кебек, бу көрәшнең инде азагы якын икәнлеген һәм бик яман буласын да белеп тора иде.

Шулай итеп, әйткәнебезчә, аның өчен төп эш Бонасье ханымны кулга төшерү иде. Д'Артаньян өчен Бонасье ханым бик газиз, бик кадерле иде шул, сөйгән ярының гомере аның өчен үз гомереннән дә кадерлерәк иде; әгәр миледи уңышсызлыкка очрый калса, Бонасье ханым аның кулында чакта, миледи үзенең дошманнары белән сөйләшеп, тәгаен үзе өчен уңайлы шартларга ирешә алыр иде. Бу бурычны инде ул хәл итте: Бонасье ханым, миледига ышанып, аны озата барачак; әгәр алар Армантьерга барып урнашсалар, миледи Бонасье ханымны, д'Артаньян Бетюнга килмәде, дип бик ансат ышандырачак. Иң күп дигәндә, ярты айдан Рошфор килеп җитәчәк: шул ярты ай эчендә исә миледи әлеге дүрт дустан үч алу әмәлен уйлап табачак. Аллага шөкер, аның эче пошарлык булмас — вакыты бик күңелле үтәр: аның характерындагы хатын-кызга үзенең үч алу ниятен камиллеккә җиткерү бик кызык булачак.

Миледи, шуларны уйлый-уйлый, бакчаны күздән кичереп, хәтерләп калырга тырышты. Ул бер үк вакытта җиңүне дә, җиңелүне дә күздә тотып, сугышның барышына карап, я алга ташланырга, я артка чигәргә әзерләнгән гаскәр башы кебек эш итә иде.

Бер сәгатьтән ул үзенә ягымлы гына бер тавыш эндәшкәнен ишетте; эндәшүче кеше Бонасье ханым иде. Яхшы күңелле назирә, әлбәттә, ризалыгын биргән иде, һәм ике яшь хатын беренче эшләре итеп бергә кичке ашка киттеләр.

Алар ишегалдына кайтып кергәч, бирегә таба килгән карета тавышы ишеттеләр.

Миледи бу тавышка колак салды.

— Сез ишетәсезме? — дип сорады.

— Әйе, капка төбенә карета килеп туктады.

— Абыем җибәргән карета ул.

— И аллам!

— Я, ярый, курыкмагыз! Батыр булыгыз!

Миледи ялгышмаган иде: монастырь капкасы төбендә кыңгырау чыңлаганы ишетелде.

— Барыгыз, булмәгезгә керегез, — диде ул Бонасье ханымга, — сезнең үзегез белән аласы кыйммәтле әйберләрегез бардыр.

— Миндә анын хатлары бар,— диде Бонасье ханым.

— Әнә шуларны алыгыз да минем янга килегез, тиз-тиз генә ашап алырбыз, безгә төн буе юлда барырга туры килмәгәе, бераз көч җыеп куярга кирәк.

— И аллам! — диде Бонасье ханым, куркәген тотып.— Йөрәгем шул хәтле каты тибә, кузгала да алмыйм.

— Курыкмагыз, батыр булыгыз дим бит! Бер чирек сәгатьтән котыласыгызны уйлагыз. Аннары бу эшләрне анын өчен эшләгәнегезне дә онытмагыз.

— Әйе шул, анын өчен эшлим! Сез бер сүзегез белән миңа рух бирдегез. Барыгыз, мин сезнең янга килермен.

Миледи ашыга-ашыга үз бүлмәсенә менде, анда аны Рошфорның хезмәтчесе көтеп тора иде — миледи аңа ниләр эшләргә икәнлеген әйтте.

Хезмәтче аны капка төбендә көтеп торырга тиеш; әгәр шул чак мушкетерлар килеп чыкса, карета бик каты чаптырып китеп, монастырьны әйләнеп узарга да урман аръягындагы кечерәк бер авылга китәргә һәм шунда миледины көтеп торырга тиеш. Ул чагында миледи бакча аша гына чыгачак та авылга җәяү барып җитәчәк; милединың бу тирәләрне бик яхшы белгәнлеген без бер тапкыр әйтеп киткән идек инде.

Әгәр инде мушкетерлар килеп чыкмаса, эш сөйләшеп куйганча була: Бонасье ханым, миледи белән тагын бер тапкыр саубуллашам дип, карета күтәрмәсенә менә дә карета шундук чаптырып китеп тә бара.

Бүлмәгә Бонасье ханым килеп керде. Миледи, анын күңелендә шик-мазар тумасын өчен, ул барында хезмәтчегә баягы боерыкларының соңгы өлешен генә әйтте.

Аннары хезмәтчегә карета хакында берничә сорау бирде; каретага өч ат җигелгән, атларны почтачы тота икән; Рошфорның хезмәтчесе форейтор * буларак каретаны озата барырга тиеш иде.

Бонасье ханымның күңелендә шик-мазар тумагае дип миледи юкка гына курыкты: ул бачара хатын артык саф күңелле, артык беркатлы иде шул, икенче бер хатын үзенә каршы шундый мәкер корыр дип уена да китерми иде; өстәвенә монастырь назирәсеннән ишеткән графиня Винтер дигән исем аңа бөтенләй таныш исем түгел, хәтта үз башыннан кичкән бу бәхетсезлекләргә ниндидер бер хатынның зур катнашы барлыгын да белми иде.

— Менә күрәсез, бөтенесе дә әзер,— диде миледи, хезмәтче чыгып киткәч.— Назирә ханым берни сизми, мине кардинал боерыгы буенча алырга килгәннәр дип уйлый. Бу кеше соңгы боерыкларны әйтергә китте. Бераз ашап алыгыз, берәр йотым шәраб эчегез, аннары кузгалырбыз.

— Әйе шул, кузгалырбыз,— диде Бонасье ханым, ихтыярсыз бер хәлдә.

---

* Очлап җигүдә алдагы атларны тотып баручы җайдак.

Миледи кулын изәп кенә аңа өстәл янына килеп утырырга кушты, рюмкасына испан шәрабы салды, тәлинкәсенә чебеш түше куйды.

— Күрәсезме, безнең эшләр нинди җайлы бара,— диде ул,— әнә караңгыланып та килә инде; таң атканда үзебезнең аулак җиребезгә барып җитәрбез, безнең кайда икәнебезне берәү дә белмәс. Ягез инде, кыюрак булыгыз, тамагыгызга берәр нәрсә капкалагыз.

Бонасье ханым, кушканга күрә генә, ике-өч кисәк ит капты, аз гына шәраб эчеп куйды.

— Эчеп бетерегез инде, эчеп бетерегез, менә миннән үрнәк алыгыз,— диде миледи, рюмкасын авызына таба китереп.

Рюмканы ирененә тидерәм дигәндә генә кулы һавада асылынып калды — миледи еракта тупыр-тупыр атлар чабышкан тавыш ишетте: бу тавыш якынайганнан-якыная барды һәм шул минутта ук диярлек ат кешнәгәне дә ишетелде.

Күк күкрәгән аваз йокыбыздан уятып, матур төшебезне бүлдергән кебек, бу тавыш та милединың шат кәефен юкка чыгарды; чырае агарынып китте, үзе шундук тәрәзәгә ташланды, Бонасье ханым исә, дер-дер калтыранып, урыныннан торды да авып китмәс өчен урындыкка таянды.

Хәзергә әле берни күренми, тупыр-тупыр итеп атлар чабышып килгәне генә ишетелә иде.

— Ай аллам, нинди тавыш ул?— дип сорады Бонасье ханым.

— Болар я безнең дусларыбыз, я дошманнарыбыз,— диде миледи, үзенә генә хас куркыныч бер салкын канлылык белән.— Шунда гына торыгыз, кемнәр икәнен хәзер әйтәм.

Бонасье ханым, таш сын шикелле тавышсыз-өнсез агарынып, урынында басып тора бирде.

Тояк тавышлары тагы да катырак ишетелә башлады, атлар инде монастырьдан йөз илле адымнар чамасында гына иде ахры; бу төштә юл борылышы булганга гына күренми иде алар. Әмма хәзер инде тояк тавышлары шул хәтле ачык ишетелә — тупырдауларына карап ничә ат икәнен дә белеп булырлык иде.

Миледи чекрәеп еракка күзләрен текәде: тышта әле тәмам караңгыланып бетмәгән — атлыларны шәйләрлек иде.

Кинәт юл борылышында укалы эшләпәләр ялтырап, җилдә каурыйлар чайкалганы күренде; миледи башта ике җайдак, аннары биш, иң соңыннан инде сигез җайдак шәйләде; берсе ике ат буе алгарак чыккан иде.

Миледи аһылдап куйды: алдан чаптырып килүче җайдакның д'Артаньян икәнлеген таныды.

— Ай аллам, ай аллам! Нәрсә бар анда? — дип эндәште Бонасье ханым.

— Кардинал гвардиячеләренең мундирлары бу, бер генә минутны да әрәм итәргә ярамый! Тизрәк качыйк! — дип кычкырды миледи.

— Әйе, әйе, качыйк! — дип кабатлады Бонасье ханым, ә үзе, коты алынып, урыныннан кузгала да алмады.

Атлы җайдакларның тәрәзә буеннан үтеп китүләре ишетелеп калды.

— Әйдәгез! Әйдәгез инде! — диде миледи, яшь ханымны кулыннан тотып, өстерәп алып китмәкче булды.— Бакча аша китеп өлгерәбез әле, монда ачкыч бар... Тизрәк ашыгыйк, тагын биш минуттан соң булыр аннары.

Бонасье ханым кузгалып китмәкче булды, бер-ике адым атлады да, аяклары тотмыйча, идәнгә ауды.

Миледи аны күтәреп алып китмәкче булды, ләкин көче җитмәде.

Шул минутта дөбер-дөбер карета киткәне ишетелде: почтачы, мушкетерларны күрү белән, атларын кушаяклатып чаптырып китеп барды. Аннары өч-дүрт тапкыр шарт-шорт мылтык атканнары ишетелде.

— Соңгы тапкыр сорыйм: китәргә исәбегез бармы сезнең?— дип кычкырды миледи.

— Ай аллам, ай аллам! Хәлем юклыгын күрәсез бит, бөтенләй атлый алмаганымны күреп торасыз бит... Үзегез генә китегез.

— Үзем генә китәмме?! Сезне монда калдырыпмы?! Юк, юк, алай булмас! — дип кычкырды миледи.

Шул вакыт ул кинәт капыл гына туктады, күзләрендә яман чаткылар чагылып китте, аннары өстәл янына йөгереп килде дә Бонасье ханымның рюмкасына, йөзек кысасын тиз генә ачып, шуның эчендәге нәрсәне салды.

Ул бөртек чаклы гына кызгылт бер нәрсә булып, шәрапка салу белән үк эреп тә бетте.

Шуннан соң миледи нык кул белән рюмканы өстәлдән алды да:

— Мәгез, эчегез, үзегезгә хәл кереп китәр, эчегез! — диде.

Шулай дип, рюмканы яшь ханымның авызына китерде, тегесе, аны-моны уйламастан, эчеп тә җибәрде.

«Эх, болай итеп үч аласы түгел идем, нишлисең бит, шулай туры килә инде»,— дип сөйләнде миледи күңеленнән, мәкерле-яман елмаеп, рюмканы өстәлгә куйды да атылып бүлмәдән чыгып китте.

Бонасье ханым аңа ияреп китә алмады, аның артыннан карап кына калды: ул төшендә үзен куа килүче явыз адәмнәрдән качарга тырышып та алардан котыла алмаган бер кеше хәлендә иде.

Шуннан соң берничә минут вакыт үтте, бик каты итеп капканы кагулары ишетелде: Бонасье ханым миледины менә-менә кире килеп керер дип көтсә дә, миледи күренмәде.

Яшь ханымның ут кебек кызышкан маңгаена — куркудан, күрәсең,— салкын тир бәреп чыкты. Ниһаять, шалтырап рәшәткәләр ачылганын ишетте, баскычта күн итекләр дөпелдәгәне, шпорлар чыңлаганы ишетелде, кешеләр шаулаша башлап, бу тавышлар һаман якынлаша барды. Бонасье ханымга шул шау-шу эчендә үз исемен ишетә кебек тоелды.

Шуннан соң ул кинәт сөенеченнән кычкырып җибәрде дә ишеккә ташланды: д'Артаньянны тавышыннан танып алды.

— Д'Артаньян! Д'Артаньян! Сезме бу? Монда керегез, монда! — дип кычкырды Бонасье ханым.

— Констанция! Констанция, кайда сез? Ай, аллам! — дип җавап кайтарды егет.

Шул мизгелдә хөҗрә ишеге ачылды да, дөресрәге, тыштан гәүдә белән этеп ачылып китте дә бүлмәгә берничә кеше чабышып килеп керде; Бонасье ханым, креслога авып, хәрәкәтсез калды.

Д'Артаньян көпшәсеннән әле һаман төтене чыгып торган пистолетын ташлады да сөйгәненең каршына килеп тезләнде; Атос пистолетын бил каешына кыстырып куйды, Портос белән Арамис кулларындагы ялангач кылычларын кыннарына салдылар.

— Һай, д'Артаньян! Бәгырем! Синең дә килер көнең булыр икән, син алдамадың мине!.. Әйе, бу син ич!

— Әйе, әйе, Констанция, без тагын икәү бергә!

— *Ул ханым* сезне килми дип никадәр ышандырырга тырышмасын, мин барыбер күңелемнән синең килереңә ышандым, китәргә теләмәдем. Аһ, бик әйбәт иткәнмен, бик бәхетлемен мин!

Тыныч кына креслога барып утырган Атос, *ул ханым* дигән сүзне ишеткәч, капыл гына сикереп торды.

— *Ханым!* Нинди *ханым* ул? — дип сорады д'Артаньян.

— Минем бер дус хатын, мине дус күреп, ул җәберләүчеләремнән качырмакчы иде; сезне кардиналның гвардиячеләре дип белеп, әле генә моннан качып чыгып китте.

— Сезнең дус хатын?! — дип кычкырып куйды д'Артаньян, чырае сөйгәненең баш япмасыннан да аграк булып агарынып китте.— Нинди дус хатынны әйтәсез сез?

— Капка төбендә аның каретасы тора иде — шул хатын, ул сезнең дустыгыз булган, д'Артаньян, сез аңа бөтен серегезне сөйләгәнсез.

— Исеме ничек, исеме? — диде д'Артаньян.— И аллам! Әллә аның исемен дә белмисезме?

— Әйе, ничек соң әле, ничек дип эндәшәләр иде... Туктагыз әле... бик гаҗәп... Ай аллам, башым әйләнә... күз алларым караңгылана...

— Дуслар, килегез әле, ярдәм итегез! — дип кычкырып җибәрде д'Артаньян.— Куллары суына, хәле бик начар. И аллам! Һушыннан язып бара бит!

Портос ярдәмгә кешеләр чакырып кычкыра башлагач, Арамис өстәл янына йөгереп килде дә стаканга су салмакчы булды, шул чакны Атосның чырае әллә нишләп үзгәреп китүен күреп, туктап калды: Атос куркудан катып калган күзләрен бер рюмкага төбәп өстәл янында басып тора, күңеленә бик яман бер шик килгән кебек иде.

— Юк!..Юк, андый хәлнең булуы мөмкин түгел! Андый җинаятькә юл куймас ходай,— дип сөйләнде үзе.

— Су бирегез, су! Су! — дип кычкырды д'Артаньян.

— Ай бичара! Бичара! — дип тавышы кысылып пышылдап куйды Атос.

Бонасье ханым, д'Артаньянның үбүенә уянып китеп, күзләрен ачты.

— Аллага шөкер! Һушына килә! — дип кычкырды егет.

— Ханым... Ханым, алла хакы өчен әйтегез әле, бу буш рюмка кемнеке? — дип сорады Атос.

— Минеке, әфәндем...— диде яшь хатын үлеп барган бер тавыш белән.

— Ә бу рюмкага шәрабны сезгә кем салды?

— *Шул ханым.*

— Кем соң ул *шул ханым*?

— Әһә, исемә төште, графиня Винтер,— диде Бонасье ханым.

Дүрт дус дүртесе берьюлы «аһ!» итеп куйдылар, тик Атос тавышы гына башкаларныкыннан катырак яңгырады.

Бонасье ханымның йөзе үлек чырае төсле агарып китте, каты әрнүдән тартышкалап куйды, һәм аннары ул, тыны бетеп, Портос белән Арамисның кулына авып төште.

Д'Артаньян әйтеп бетергесез бер шом-хафа белән Атосның кулыннан тотып алды:

— Шул хәл булыр дип уйлыйсыңмы син?..

Егетнең тавышы үкереп елый башлаган сыман ишетелде.

— Барысы да булуы мөмкин дип уйлыйм мин,— диде Атос, ут йотуын тышка чыгармас өчен чытырдатып иренен тешләде.

— Д'Артаньян, д'Артаньян! — дип кычкырды Бонасье ханым.— Кайда син? Ташлама мине, күрәсең бит, үлеп барам!

Әле һаман тетрәнә-тетрәнә Атосның кулын кысып торган д'Артаньян аның кулын җибәрде дә Бонасье ханым янына ташланды.

Хатынның чибәр йөзе үлем газабыннан ямьсезләнеп киткән, күзләре калайланып мәгънәле төсен югалткан, бөтен тәне калтыранып тартыша, маңгаеннан шыбырдап тир тамчылары ага иде.

— Алла хакы өчен, йөгерегез әле тизрәк, чакырыгыз әле берәрсен... Портос, Арамис, ярдәм сорагыз әле!

— Барыбер файдасы юк инде, ул хатын эчерткән агудан дәва юк,— диде Атос.

— Әйе, әйе, ярдәм итегез! Ярдәм итегез! — дип пышылдады Бонасье ханым.

Шуннан соң ул, актык көчен туплап, ике кулы белән егетнең башыннан тотты да, шушы күз карашына бөтен җаныннкүңелен салган сыман, сөйгәненең йөзенә тилмереп карады һәм «аһ!» дип куйды да иреннәрен егетнең иренелә тидерде.

— Констанция! Констанция!» — дип эндәште д'Артаньян.

Бонасье ханымның «аһ!» дигән авазы д'Артаньянның авызына кагылып китте — ханымның өзелеп-янып сөйгән керсез, пакь җаны күккә ашты.

Д'Артаньян аның үле гәүдәсен кочагына кысты.

Егет ачыргаланып кычкырып куйды да, сөйгәне шикелле үк агарынып, тәне суынып, аның янына ауды.

Портос үксеп елап җибәрде, Атос гарешкә карап йодрык янады, Арамис чукынгалап алды.

Шул минутта ишектә бер ят кеше күренде, бүлмәдәгеләрнеке төсле үк диярлек аның да чырае агарынган иде — як-ягына күз салгалап алу белән җансыз калган Бонасье ханым белән һушсыз егылып яткан д'Артаньянны искәрде.

Зур фаҗигалардан соң була торган мингерәп өнсез калу мизгелендә килеп керде ул.

— Ялгышмаганмын икән: менә д'Артаньян әфәнде, ә сез аның өч дусты, Атос, Портос һәм Арамис әфәнделәр, — диде әлеге кеше.

Өч дус үзләренең исемнәрен әйткән бу кешегә гаҗәпләнеп карадылар; бу кешене менә-менә таныйрлар кебек тоелды аларга.

— Әфәнделәр, сез дә минем кебек үк бер хатынны эзлисездер, — дип сөйләвендә дәвам итте ят кеше, аннары әллә нинди генә куркыныч бер төс белән елмаеп әйтә куйды: — Ул хатын монда булган бугай инде, чөнки мәет күрәм мин монда! — диде.

Өч дус һаман тавышсыз-өнсез тора бирделәр; бу кешенең дә тавышы аларга кайчандыр күргән бер кешеләрен хәтерләтте; ләкин кайда ничек ишеткәнлекләрен исләренә төшерә алмадылар.

— Әфәнделәр, — дип ят кеше янә сүзгә кереште, — ике тапкыр исән калуым өчен үзегезгә бурычлы булган кешене сез танырга теләмәгәч, исемемне үземә әйтергә туры килә инде. Мин — лорд Винтер, шул хатынның каенагасы булам.

Өч дус гаҗәпләнүләреннән кычкырып куйдылар.

Атос, торып, лорд Винтерга кул бирде.

— Рәхим итегез, милорд, бергәләп эшкә керешербез, — диде ул.

— Мин ул хатыннан биш сәгатькә генә соңгарып, Портсмуттан чыгып киттем, — дип сөйли башлады лорд Винтер, — аннан өч сәгатькә генә соңга калып Булоньга килеп җиттем, Сен-Омерда егерме минутка гына өлерми калдым һәм шуннан соң Лильерда аның эзен югалттым. Мин аннары тәвәккәлләп, кешеләрдән сораша-сораша киттем, шуннан сез атларыгызны бик каты чаптырып минем яннан узып киттегез; мин д'Артаньян әфәндене танып калдым. Сезгә эндәшкән дә идем, сез җавап бирмәдегез; артыгыздан куа китмәкче идем дә, минем ат бик өшәнгән иде, сезнекеләр шикелле каты чаба алмады. Шулай да, никадәр ашыксагыз да, сез дә шактый соңга калгансыз бугай!

— Күреп торасыз,— диде Атос, тынсыз яткан Бонасье ханым белән д'Артаньянны лорд Винтерга күрсәтеп. Портос белән Арамис д'Артаньянны һушына китерергә маташалар иде.

— Икесе дә үлгәнме? — дип сорады лорд Винтер тыныч кына.

— Бәхеткә каршы, икесе дә түгел, д'Артаньян әфәнде һушын гына җуйды,— диде Атос.

— Ә, алайса яхшы! — диде лорд Винтер.

Чыннан да, шул минутта д'Артаньян күзен ачты.

Егет Портос белән Арамис кулыннан ычкынды да, шашкан кебек, сөйгәненең үле гәүдәсенә ташланды.

Атос, торып, тантаналы бер кыяфәт белән ашыкмый гына дусты янына килде дә аны иплэп кенә кочаклап алды, д'Артаньян үксеп елап җибәргәч, Атос тәэсирле, матур тавышы белән әйтте:

— Дустым, ир-егет бул: ирләр үлсә, хатыннар елый, хатыннар үлсә, ирләр алар өчен үч ала! — диде.

— Әйе! Шулай! — диде д'Артаньян.— Сөйгәнемнең үчен кайтару өчен мин синең белән теләсә кая китәргә әзермен!

Атос, үч алу өмете шул минутта бичара дустына беркадәр рух бирүеннән файдаланып, Портос белән Арамиска ымлап кына монастырь назирәсен чакырып килергә кушты.

Портос белән Арамис назирәне шушы хәлләрдән тәмам аптырап каушап калган, әсәрләнгән бер хәлендә коридорда очраттылар; назирә берничә монах хатынны чакырып китерде һәм, монастырь йолаларына сыешмаса да, бу хатыннар биш ир янына килделәр.

Атос, д'Артаньянны култыклап алып, монастырь назирәсенә мөрәҗәгать итте:

— Ханым, бу мескен хатынның гәүдәсен инде без сезгә — дин кешеләренә тапшырабыз. Күккә ашып фәрештә булганчы ул җирдә дә бер фәрештә иде. Сез аны монастырегызның бер баласы итеп җирләгез инде, без бервакыт аның каберенә килеп зиярәт кылырбыз әле.

Д'Артаньян, битен Атосның күкрәгенә каплап, үксеп елап җибәрде.

— Ела, ела, синең йөрәгең тулы дәрт, сөю ялкыны! Эх, мин дә синең кебек елый алсам! — диде Атос һәм егетне әтисе кебек яратып, изге ата кебек юата-юата, үзе дә күпне кичергән бер кеше буларак олы җанлылыгын күрсәтеп, алып чыгып китте.

Алар бишәүләп, үзләренең атларын җитәкләгән хезмәтчеләрен дә ияртеп, еракта бистәләре күренеп торган Бетюн каласына таба юл тоттылар һәм юлларында очраган беренче кунакханә каршысына килеп туктадылар.

— Нигә без ул хатынның артыннан куа китмәдек? — дип сорады д'Артаньян.

— Ул эшне куеп торабыз әле, башта кайбер чаралар күрәсе бар,— диде Атос.

— Бездән качып котылачак бит ул, качып котылачак, Атос, аннары син гаепле булачаксың! — диде егет борчылып.

— Аньсы өчен үзем җавап бирәм,— диде Атос.

Д'Артаньян, өлкән дустына бик ышанганлыктан, башын аска иде дә бүтән бер сүз эндәшмәде, кунакханәгә керде.

Портос белән Арамис исә, Атосның бу кадәр ышаныч белән сөйләшүенә сәерсенеп, күзгә-күз карашып алдылар.

Лорд Винтер Атосны д'Артаньянның кайгысын җиңеләйтер өчен генә әйтә моны дип уйлады.

Кунакханәдә биш буш бүлмә барлыгын белгәч, Атос:

— Хәзер инде, әфәнделәр, һәркайсыбыз үз бүлмәсенә керсен. Д'Артаньянга, ялгызы гына калып, туйганчы еларга, аннары йоклап алырга кирәк. Тыныч булыгыз, бөтен эшне мин үз өстемә алам,— диде.

— Шулай да, минемчә, графиняга каршы берәр төрле чара күрергә кирәк булса, аньсы минем эш, чөнки ул безнең килен,— дип куйды лорд Винтер.

— Минеке дә ул эш, чөнки ул минем хатыным,— диде Атос.

Д'Артаньян көлемсерәп куйды: Атосның, инде мондый серен фаш иткәч, үч аласына тәгаен ышанып эш итүен төшенде ул. Портос белән Арамис, агарынып китеп, күзгә-күз карашып алдылар. Лорд Винтер исә Атосны акылыннан язган ахры дип уйлады.

— Шулай итеп, һәркайсыбыз үз бүлмәсенә кереп китә,— дип сүзен кабатлады Атос,— ә миңа үземә генә эш итәргә ирек бирегез. Моның минем эш икәнлеген үзегез күреп торасыз бит, чөнки мин ул хатынның ире. Д'Артаньян, югалтмаган булсагыз, теге кешенең эшләпәсе эченнән төшеп калган кәгазьне миңа бирегез әле, анда бер авыл исеме язылган булырга тиеш...

— Әһә, төшендем! — дип куйды д'Артаньян.— Ул авыл исеме аның кулы белән язылган.

— Үзең дә күреп торасың: күктә ходай бар ул! — диде Атос.

## XXXIV

## КЫЗЫЛ ПЛАЩЛЫ КЕШЕ

Атосның ачыну-өзгәләнүе әчке бер кайгысына әйләнеп, аның акыл сәләтен тагы да көчәйтеп җибәрде.

Биргән вәгъдәсе, үз өстенә алган җаваплылык турында уйлана-уйлана, ул бүлмәсенә иң азактан кереп китте, кунакханә хуҗасыннан бу төбәкнең картасын сорап китертте дә, карта өстенә иелеп, шундагы сызыкларны күзеннән кичерде, Бетюннан Армантьерга дүрт төрле юл бара икәнлеген белгәч, хезмәтчеләрне чакырып китерергә кушты.

Планше, Гримо, Мушкетон һәм Базен, Атос янына килеп, аннан ачык, төгәл һәм төпле боерыклар алдылар.

Алар иртә таңда, һәркайсы үз юлы белән, Армантьерга китәргә тиеш иделәр. Планше, арада иң зирәге буларак, карета чаптырып киткән юл белән барырга тиеш булды. Укучылар ул каретаны Рошфорның хезмәтчесе озата китүен һәм безнең дүрт дусның шул каретага атып калуларын онытмаганнардыр.

Атосның бу эшкә хезмәтчеләрне дә кушуының беренче сәбәбе шул — үзенә һәм дусларына хезмәт иткән вакыт эчендә ул аларның һәркайсының яхшы гына сыйфатларын күреп өлгергән иде. Аннан ары, узгынчы кешеләрдән тегене-моны сорашкан чакта хезмәтчеләр хуҗа әфәнделәренә караганда әзрәк шик тудыралар һәм ул кешеләр алар белән ачылыбрак та сөйләшәләр. Тагын шул ягы да бар: миледи аларның хуҗа әфәнделәрен танып белсә дә, хезмәтчеләрнең үзләрен күреп белми, хезмәтчеләр исә, киресенчә, аны бик яхшы беләләр иде.

Иртәгесен алар сәгать унбердә сөйләшенгән төштә дүртәү очрашырга тиешләр. Әгәр милединың кайда качып ятканын белә алсалар, өчесе аны саклый калырга, ә дүртенчесе Бетюнга кайтып, хәлне Атоска әйтергә дә дүрт дусны шунда ияртеп килергә тиеш иде.

Шушы күрсәтмәләрне алганнан соң, хезмәтчеләр чыгып киттеләр.

Атос, урыныннан торып, биленә кылычын асты, өстенә плащын бөркәнде дә кунакханәдән чыгып китте. Сәгать уннар тирәсе иде. Белгәнебезчә, кичке сәгать унда провинция каласының урамнарында инде кеше әсәре калмый, әмма шунысы да тәгаен: Атос нәрсәнедер сорашып белешү өчен берәр кеше эзли иде. Ахырында ул соңга калып кайтып килүче бер кешегә юлыкты, аның янына килеп, бер-ике җөмлә сүз әйтте. Бу кеше куркуыннан чигенеп куйды, шулай да мушкетерның сүзенә җавап итеп кая табадыр кулын сузып күрсәтте. Атос бу кешегә, мине шунда илтеп куйсаң, ярты пистоль акча бирәм, дип тә әйтеп карады, тик әлеге кеше моңа риза булмады.

Атос бу кеше бармагы белән төртеп күрсәткән урам буйлап арырак китте, урам чатына җиткәч, тагын туктады, кай якка таба китәргә белмичә аптырабрак калды, күрәсең. Урам чатында берәрсе очрамый калмас әле дип, басып тора бирде. Чыннан да, бераздан төнге каравылчы узып китте. Атос моңа да эндәшеп, теге соравын әйтте, бу каравылчы да, теге кеше шикелле куркып-сискәнеп китте, Атосны озатып куярга риза булмады, кулын сузып юлны гына күрсәтте.

Атос, күрсәткән якка таба китеп, кала читендәге бистәгә җитте—бу бистә алар калага килеп кергән төштән капма-каршы якта иде. Монда җиткәч, Атос тагын аптырашта калды ахры — өченче тапкыр туктады.

Бәхетенә каршы, яныннан бер хәерче узып бар иде. Ул, Атос янына туктап, хәер сорана башлады. Атос аңа, бара торган

җиремә илтеп куйсаң, бер экю акча бирермен, диде. Хәерче башта икеләнебрәк торды, аннары караңгыда көмеш тәңкә ялтыраганын күреп алгач, риза булды, Атосны иярткеп китте.

Бер урам чатына җиткәч, ул еракган гына Атоска аулак бер урында аерым утырган шыксыз гына кечерәк бер йорт күрсәтте. Атос шул йортка таба китте, хәерче исә, акчаны алу белән, кире элдертте.

Атос, әлеге йортны тирәли әйләнеп чыккач кына, кан-кызылга буялган стенасыннан ишеген шәйләп алды; тәрәзә капкачы ярыкларыннан берннинди якты-мазар күренми, эчтә кеше барлыгын сиздерердәй бернинди тавыш-өн дә ишетелми; гүр эче кебек дөм-караңгы һәм тып-тын иде ул.

Атос ишекне бер, ике, өч тапкыр шакыды — җавап бирүче булмады, шулай да өченче тапкыр шакыганнан соң, эчтән бирегә таба атлаган аяк тавышы ишетелде; аннары ишек ярты-лаш ачылды да аннан ак чырайлы, кара чәчле, кара сакаллы озын гына бер кеше күренде.

Атос белән әлеге ят кеше бераз нидер сөйләшеп алдылар, шуннан соң озын буйлы кеше мушкетерга кулын изәп өйгә керергә мөмкин икәнлеген белгертте. Атос бу рөхсәттән шундук файдаланып калырга тырышты, һәм алар ишекне ябып өйгә кереп киттеләр.

Атосның шундый ерак җиргә шундый зур кыенлык белән эзләп килгән бу кешесе аны кабинетына алып керде. Ишек ачар алдыннан гына ул тимер чыбык белән кеше скелеты сөякләрен җыеп-беркетеп утырган икән, скелет үзе инде җыелып беткән, тик баш сөяге генә өстәлдә аерым ята иде.

Бүлмәнең башка җиһазлары да йорт хуҗасының табигать гыйлеме белән шөгыльләнгәнлеген әйтеп тора иде: пыяла савытларга төрле-төрле еланнар салынып, тышына һәр төрнең исеме язып куелган; кара агачтан ясалган рам эчендәге кип-терелгән кәлтәләр зөбәрҗәт ташы төсле булып елтырашып торалар; бүлмәнең почмакларына, түшәмгә, бәйләм-бәйләм кыр үләннәре асып куелган — алар хуш исле, гади кешеләр белеп бетерми торган шифалы-сихәтле үләннәрдер, күрәсең. Йорт хуҗасының янында гаиләсе һәм хезмәтчесе юклыгы да сизелеп тора: озын буйлы бу кеше биредә ялгызы гына яши иде.

Без тасвирлап узган әлеге җиһазларны Атос тыныч кына күздән кичерде дә, эзләп тапкан кешесенең чакыруы буенча, урындыкка килеп утырды.

Шуннан соң ул үзенең йомышын, нинди ярдәм сорап килүен әйтте, әмма Атос үзенең үтенечен әйтү белән үк, аның каршында басып торган ят кеше куркынып китеп, артына чигеп куйды, ярдәм итүдән баш тартты. Шуннан соң Атос кесәсеннән нибары ике генә юл язылып, шуңа кул куелган, печать сугылган бер кәгазь чыгарды да бик тиз баш тартырга ашыккан әлеге кешегә күрсәтте. Озын буйлы кеше шул ике юлны укып, имзаны күргәч һәм печатьне таныгач та, хәзер каршылыгым юк, баш өсте дигәнне аңлатып баш иде.

Атоска шул гына кирәк иде; ул, торып хуҗа белән саубуллашты да чыгып китте, килгән юлы белән кире кайтып китте, кунакханәгә кайтып җиткәч инде, бүлмәсенә кереп бикләнде.

Иртә таңда аның янына д'Артаньян кереп, «нишләргә?» — дип сорады.

— Көтәргә,— дип җавап бирде Атос.

Озакламый монастырь назирәсе мушкетерларга мәрхүмәне төш вакытында күмәчәкләрен хәбәр иттерде. Аны агулап үтерүчегә килгәндә исә, анысы хакында берни әйтә алмыйлар икән; бакча аша чыгып качкан дип уйлыйлар: бакчадагы комда аяк эзләре бар икән, бакча капкасы бикле, ә капканың ачкычы юкка чыккан икән.

Лорд Винтер белән дүрт дус әйтелгән вакытка монастырьга килделәр; монастырьда инде чаң-чоң китереп чаң кага башлаганнар, часовня ишеге ачып куелган, тик клирос рәшәткәсе ябык иде. Клирос уртасына табут белән, монастырьда яшәүчеләр киемендә, явызлык корбанының мәете куелган. Клиросның як-ягында, рәшәткә артында — туп-туры монастырьдан килеп керә торган төштә, кармелиткалар җыелышып басканнар; алар шуннан җеназа укыганны тыңлап торалар, изге аталар тавышына кушылып-кушылып җырлыйлар,— алар фани дөнья кешеләрен күрмиләр, үзләре дә аларга күренмиләр иде.

Часовня ишегенә якынрак килә башлагач, д'Артаньян тагын хәле китә башлавын тойды; борылып, күзләре белән Атосны эзләде, әмма Атос юкка чыккан иде.

Атос, үз өстенә алган үч кайтару бурычына тугрылык саклап, үзен бакчага алып чыгуларын үтенгән иде; кая барса да үз артыннан канлы эз калдыручы теге хатынның ком өстенә төшеп калган җиңелчә аяк эзе буйлап атлый торгач, ул урман авызына караган капка янына җитте, капканы ачтырып, урманга кереп китте.

Аның алдан уйлаганнары барысы да дөрескә чыкты: карета борылып кереп киткән юл урман кырыеннан урап узган иде. Атос, күзен җиргә текәп, беркадәр ара шул юл буйлап барды; әледән-әле күзенә җиргә тамып калган кан тамчылары чалынды — монысы инде я атка атланып каретаны озата барган кешенең, я бер атның яраланган булуын күрсәтә иде. Монастырьдан өч чирек лье чамасы киткәч, Фестюбердан илле адымнарда юлда зуррак кан табы күренде, шул тап тирәсендәге җирне атлар таптап бетергән иде. Урман белән шушы канлы урын арасында, ат тояклары җирне уйгалаган төштән беразчиттәрәк, бакчадагы шикелле үк вак-вак атлаган аяк эзләре төшеп калган, карета шунда туктаган булган, күрәсең.

Шушы төштә миледи урманнан чыгып, каретага утырган иде.

Атос, үзенең гөманнарын раслаган шушы ачышларына сөенеп, кунакханәгә кайтты һәм анда үзен түземсезләнеп көтеп торган Планшены очратты.

Атос шикелле үк, Планше да юлдан барган чагында кан

таплары күргән, атлар тукталган төшне дә искәргән икән; шул урыннан соң инде Атос кире кайтты, Планше исә арырак киткән һәм Фестюбер авылында, трактирда шәраб эчеп утырганда, беркемнән сорашмый-нитми, хәлне белгән: моннан алдагы көнне, кичке сәгать тугызынчы яртыда, почта каретасына утырып килгән бер ханымны озата баручы бер кеше, яраланган булганлыктан, юлын дәвам иттерә алмыйча тукталырга мәҗбүр булган. Каретада килүчеләр бу хәлне кеше талаучылар эше итеп күрсәткәннәр, урманда каретабызга ташландылар, дигәннәр. Яралы кеше авылда калган, хатын исә, атларны алмаштырып, китеп барган.

Планше почта йөртүчене эзләп тапкан. Ул кеше әлеге ханымны Фромельгә чаклы илтеп куйган, Фромельдән инде хатын Армантьерга киткән. Планше туп-туры ике авыл арасындагы юлдан гына китеп, иртәнге җидегә Армантьерга барып җиткән.

Анда почта станциясе янында бер генә кунакханә бар икән. Планше шунда эшсез калып эш эзләүче бер хезмәтче булып барып кергән. Кунакханә хезмәтчеләре белән бер ун минут та сөйләшеп өлгермәгән — шул хәлне белгән: алдагы көнне генә, төнге сәгать унбердә, бирегә, ялгызы гына ниндидер бер хатын килеп, бүлмә алган, аннары үз янына кунакханә смотрителен чакыртып, беркадәр вакыт Армантьер тирәсендә яшәргә теләвен әйткән.

Планше үзенә кирәк булганнарның барысын да белгән. Шуннан тиз генә очрашасы урынга йөгереп, сөйләшенгәнчә, анда калган өч хезмәтче белән очрашкан, аларга кунакханәнең барлык ишекләрен күзәтеп-саклап торырга кушкан да кире Атос янына йөгергән. Атосның дуслары, мәрхүмәне күмеп, мушкетерның бүлмәсенә кайтап кергәндә, Планше әле һаман җыйган мәгълүматларын сөйләп тора иде.

Бөтенесенең дә төс-чырае, хәтта Арамисның басынкы-сабыр кыяфәте дә, бик караңгы-төмсә иде.

— Нишләргә? — дип сорады д'Артаньян.

— Көтәргә,— диде Атос.

Шуннан соң барысы да үз бүлмәләренә таралыштылар.

Кичке сәгать сигездә Атос атларны иярләп куярга һәм лорд Винтер белән дусларына юлга җыенсыннар дип әйтергә кушты.

Күз ачып йомган арада бишесе дә юлга әзерләнеп беттеләр. Һәркайсы коралын тикшереп, тәртипкә китерде. Атос түбәнгә иң соңгы кеше булып төште, д'Артаньян инде атына атланып та алган, тизрәк кузгалыйк дип ашыктыра башлаган иде.

— Бераз гына сабыр итегез, бер кешебез җитешми әле,— диде Атос.

Дүрт атлы җайдак гаҗәпләнеп тирә-якка каранды; һәркайсы күңеленнән «кем җитешми соң?» дип юкка гына баш ватты.

Ул арада Планше Атоска атын китерде; мушкетер ялт кына сикереп ияргә атланды.

— Мине көтеп торыгыз, мин хәзер кайтам,— диде дә атын чаптырып китеп барды.

Чирек сәгать чамасы вакыттан соң Атос чыннан да әйләнеп кайтты, зур кызыл плащка төренгән, битлек кигән бер кеше дә иярткән иде ул.

Лорд Винтер белән өч мушкетер «Бу кем?» дигәндәй берберенә карашып алдылар. Аларның берсе дә бу кешене белми, аның кем икәнлеген әйтеп бирә алмый иде. Шулай да күцелләреннән, моны Атос эшләгән икән, шулай кирәктер, дип уйладылар.

Кичке сәгать тугызда Планше җитәкчелегендәге кечерәк бер кавалькада карета узган юл буйлап кузгалып китте.

Чырайлары өметсезлек төсле караңгы, үч тойгысы төсле куркыныч булган бу алты кеше, үз уйларына чумып, тып-тын гына, кайгы-хәсрәтле бер тамаша сыман баралар иде.

## XXXV

## ХӨКЕМ

Төн караңгы, җилле-давыллы; күк йөзеннән, йолдызларны каплап, авыр-авыр кара болытлар агыла; ай төн уртасы җиткәч кенә калкырга тиеш иде.

Вакыт-вакыт күк читендә яшьнәгән яшен яктысында еракка таба сузылган аулак юл ап-ак булып яктырып китә дә тагын бөтен дөнья дөм-караңгыга чума.

Атос әледән-әле төркемне узып алгарак киткән д'Артаньянны кире чакырып, үзләре белән бергә барырга куша, тик д'Артаньян бераздан ук тагын алга чыга, чөнки егетнең күцелендә бер генә теләк — алга ашкыну теләге генә бар иде.

Атлы җайдаклар, сүзсез-өнсез генә, теге яралы хезмәтче торып калган Фестюбер авылын уздылар да атларын чаптырып Ришбург урманы буйлап киттеләр; Эрлиега җиткәч, кавалькадага юл күрсәтеп барган Планше сулга борылды.

Әле лорд Винтер, әле Портос, әле Арамис кызыл плащлы кешегә берничә тапкыр сүз катып карадылар, тик бу кеше үзенә бирелгән сорауларга, актан-карадан бер сүз әйтмичә, баш иеп кенә җавап кайтарды. Ят кешенең болай сөйләшмәвенең сәбәбе бардыр дип, юлчылар шуннан соң аңа сүз катмас булдылар.

Ул арада яшен болытлары куерганнан-куера барды, ялт та йолт яшен яшьнәде, дөбер-шатыр күк күкрәде, давыл хәбәрчесе җил, сызгырып-сызгырып, җайдакларның эшләпә каурыйларын һәм чәчләрен тузгытты.

Кавалькада атларны эре-эре адым белән юрттырып китте.

Фромельне узып, бераз баргач та яшенләп-күкрәп яңгыр яварга тотынды; җайдаклар плащларына төренделәр; аларның

әле тагын өч лье чамасы җир барасылары бар иде, бу юлны коеп яуган яңгыр астында уздылар.

Д'Артаньян башыннан эшләпәсен салып, плащын ачып җибәрде; ут кебек кызышкан маңгае һәм бизгәк тоткан сыман калтыранган тәннәре яңгырда рәхәтләнеп китте.

Кавалькада, Госкальне артта калдырып, почта станциясенә кереп килгәндә, яңгырдан ышыкланып агачка сыенып торган бер кеше юл уртасына чыкты да бармагын авызына куйды.

Атос моның Гримо икәнлеген танып алды.

— Ни булды? Әллә Армантьердан китеп бардымы? — дип кычкырды д'Артаньян.

Гримо «әйе» дип баш какты. Д'Артаньян тешен кысып куйды.

— Тик кенә тор әле, д'Артаньян! — дип боерды аңа Атос.— Бөтен эшне мин үз өстемә алдым, шулай булгач, Гримодан мин сорашам,— диде.

— Ул хатын кайда? — дип сорады Гримодан.

Гримо Лис елгасына таба кулын сузып күрсәтте.

— Моннан еракмы? — дип сорады Атос.

Гримо хуҗа әфәндесенә имән бармагын бөгеп күрсәтте.

— Ялгызы гынамы? — дип сорады Атос.

Гримо «әйе» дип баш какты.

— Әфәнделәр, ул хатын ялгызы гына, моннан ярты льеда, елгага таба,— диде Атос.

— Яхшы, әйдә, Гримо, алып бар безне,— диде д'Артаньян.

Гримо кыр өсләтеп кенә алга таба китте, кавалькада аның артыннан иярде.

Бер илле адымнан кечкенә генә бер инеш очрап, аны аркылы чыктылар.

Ялт иткән яшен яктысында җайдакларга Энгенгем авылы күренеп китте.

— Шундамы ул, Гримо? — дип сорады Атос.

Гримо «түгел» дип башын чайкады.

— Әкренрәк, әфәнделәр! — диде Атос.

Отряд баруында дәвам итте.

Тагын ялт итеп яшен яшьнәде; Гримо алга таба кулын сузды һәм камчы шикелле бормаланып сызылган зәп-зәңгәр яшен яктысында җайдаклар паромнан йөз адым чамасында елга яры өстендә ялгыз бер йорт күреп калдылар.

Йортның бер тәрәзәсендә ут яктысы бар иде.

— Максатыбызга килеп җиттек,— диде Атос.

Шул минутта канаудан бер кеше сикереп торды; бусы Мушкетон иде; ул бармагы белән якты тәрәзәгә төртеп күрсәтте дә:

— Ул анда,— диде.

— Ә Базен? — дип сорады Атос.

— Мин тәрәзәне каравылладым, ә ул ишекне.

— Яхшы, барыгыз да бик тугрылыклы хезмәтчеләр сез,— диде Атос аларны мактап.

Атос, атыннан төшеп, тезгенне Гримога тоттырды да калганнарга йортны әйләнеп ишек янына барыгыз дип ишарәләде, үзе тәрәзәгә таба китте.

Йортны ике-өч фут биеклегендә койма төсле булып куаклар каплап алган иде. Атос куак аша сикереп төште дә тәрәзә төбенә килде. Тәрәзәнең капкачлары булмаса да, ярты биеклегенә элгән пәрдәсе тоташ корып куелган иде.

Атос, стенадагы таш кырыена басып, пәрдә өстеннән бүлмәгә күз салды.

Лампа яктысында карасу-коңгырт мантильяга төренеп утырган бер хатын-кыз күрде; бу хатын, терсәкләре белән өстәлгә таянып, фил сөягеннән кырып ясалгандай ап-ак кулларын яңакларына куеп, артсыз урындыкта сүнеп барган учак каршысында утыра иде.

Йөзен күреп булмаса да, Атосның иреннәрендә усал бер елмаю галәмәте чагылып китте: мушкетер ялгышмаган, бу хатын нәкъ ул эзләгән кеше иде.

Шул вакыт кинәт ат кешнәп җибәрде. Миледи башын күтәреп карауга, Атосның тәрәзә пыяласына капланган ак чыраен күреп, кычкырып куйды.

Атос хатынның аны таныганлыгын төшенде, тезе һәм кулы белән тәрәзәне этүгә, рам оясыннан кубып, пыялалары чылтырап коелды...

Атос бүлмә эченә сикереп төште дә, үч алучы бер рух шикелле, миледи каршына килеп басты.

Миледи ишеккә таба ташланып, ишекне ачты: бусагада Атоска караганда да агарынарак төшкән тагы да усалрак чырайлы д'Артаньян басып тора иде.

Миледи, кычкырып куеп, артка кайшалды. Д'Артаньян, аның качарлык җае бар әле, бездән тагын качып котылмагае дип уйлап, биленнән пистолетын тартып алды, ләкин шунда Атос кулын күтәрде.

— Коралыгызны кире куегыз, д'Артаньян,— диде ул,— бу хатынны үтерергә түгел, хөкем итәргә кирәк. Бераз сабыр итсәң, д'Артаньян, бик канәгать булырсың. Керегез, әфәнделәр.

Д'Артаньян аның кушканына карышмады: Атосның, алладан килгән хакимнеке кебек, тавышы тантаналы, кул изәве катгый иде. Д'Артаньян артыннан бүлмәгә Портос, Арамис, лорд Винтер һәм кызыл плащлы кеше килеп керделәр.

Хезмәтчеләр ишек, тәрәзәләрне саклый калдылар.

Миледи урындыкка килеп утырды да, бу коточкыч хәлне дога укып эфсенләгән шикелле, кулларын алга сузды; каенагасын күрүгә, ачы бер тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Ни кирәк сезгә?! — диде.

— Безгә Шарлотта Баксон кирәк,— диде Атос.— Башта аны графиня де ла Фер дип, аннары леди Винтер, баронесса Шеффильд дип атаганнар.

— Мин ул, мин ул! Миннән сезгә ни кирәк? — дип сөйләнде миледи коты алынып.

— Без сезне җинаятьләрегез өчен хөкем итәбез, сезнең үзүзегезне яклау ирегегез бар, булдыра алсагыз, үзегезне аклап карагыз. Д'Артаньян әфәнде, беренче булып сез гаеплисез,— диде Атос.

Д'Артаньян алгарак чыгып басты.

— Ходай һәм кешеләр каршында мин бу хатынны кичә кич вафат булган Констанция Бонасьены агулап үтерүдә гаеплим,— диде ул.

Шулай дигәч, Портос белән Арамиска таба борылды.

— Без моңа шаһит,— диделәр ике мушкетер.

Д'Артаньян сүзендә дәвам итте:

— Ходай белән кешеләр каршында мин бу хатынны тагын шундый җинаять кылуда гаеплим: ул шәрабка агу кушып, мине агулап үтермәкче булды, шул шәрабны ул, дусларыгызның бүләге дигән ялган хат белән, миңа Вильруадан җибәргән иде. Әмма ходай мине саклап калды, минем урынга Бризмон исемле икенче бер кеше үлде.

— Без моңа шаһит,— диделәр Портос белән Арамис.

— Ходай белән кешеләр каршында мин бу хатынны тагын шундый җинаять кылуда гаеплим: мине ул граф де Вардны үтерергә котыртмакчы булды. Биредә бу гаепне расларлык кеше булмау сәбәпле, моңа мин үзем шаһит булам. Минем сүзем бетте.

Д'Артаньян, Портос һәм Арамис белән бергәләп, бүлмәнең икенче ягына чыгып басты.

— Сезнең нәүбәт, милорд! — диде Атос.

Барон алгарак чыгып басты.

— Ходай белән кешеләр каршында мин бу хатынны шундый җинаять кылуда гаеплим: аның котыртуы буенча герцог Бекингэмны үтерделәр.

Шундагылар барысы беравыздан:

— Герцог Бекингэмны үтергәннәр! — дип кычкырып әйтеп куйдылар.

— Әйе, үтерделәр! — диде барон.— Мине искәрткән хатыгызны алгач, мин бу хатынны кулга алдырып, үземә тугрылыклы һәм ышанычлы бер кешегә аны сакларга тапшырган идем; бу хатын аны юлдан яздырып, кулына хәнҗәр тоттырып, герцогны үтерергә котырткан. Шушы минутта, бәлки, бу явыз хатынның җинаяте өчен Фельтонның башын да кискәннәрдер инде.

Хакимнәр, үзләре белеп бетермәгән бу явызлыкларны ишеткәч, тетрәнеп киттеләр.

— Бетмәде әле,— диде лорд Винтер,— сезне үзенең варисы иткән минем туганым нибары өч кенә сәгать авырып үлеп тә китте. Авыруы бик сәер иде аның, бөтен тәненә күк таплар тибеп чыкты. Сеңлем, нәрсәдән үлде сезнең ирегез?

— Коточкыч! — дип куйдылар Портос белән Арамис.

— Бекингэмны, Фельтонны һәм минем туганымны үтерде ул,

мин гадел хөкем ясалуын сорыйм һәм әйтеп куям: әгәр андый хөкем булмаса, мин аны үзем җиренә җиткерәм.

Лорд Винтер, башка гаепләүчегә урын биреп, д'Артаньян янына барып басты.

Миледи, башын кулларына салып, үлем куркынычыннан чуалып киткән уйларын тупларга тырышкан сыман булды.

— Хәзер минем нәүбәт,— диде Атос һәм елан күргән арслан шикелле калтырана башлады,— минем нәүбәт. Бу хатынга мин әле яшь кенә кыз чагында, бөтен гаиләбезнең теләгенә каршы килеп өйләнгән идем. Мин аңа байлык бирдем, үз исемемне бирдем һәм шуннан соң көннәрдән бер көнне бу хатынның хурлык тамгасы барлыгын белдем: аның сул як кулбашына ләлә чәчкәсе рәвешендә хурлык тамгасы сугылган.

Миледи:

— О! — дип куйды да урыныннан торды.— Тәгаен әйтәм: миңа шундый кабахәт хөкем карары чыгарган судны да, ул карарны башкарган кешесен дә таба алмассыз.

— Туктагыз! Анысына мин җавап бирәм! — диде берәү.

Шуннан кызыл плащлы кеше алга чыгып басты.

Миледи, куркуыннан тыны буылып:

— Кем бу, кем бу? — дип кычкырды; чәчләре тузгып, үлек чырае кергән йөзенә төште дә тере шикелле кыймылдашып тора башлады.

Бөтенесе күзләрен әлеге кешегә төбәделәр: Атостан башка аны берсе дә белми иде.

Башкалар кебек, Атос үзе дә бу кешегә гаҗәпләнеп карап тора, шушы минутта тәмамланып килгән коточкыч фаҗигага бу кешенең дә нинди катнашы булды икән? — дип аптырап уйланып тора иде.

Ят кеше тантаналы, салмак бер адым белән миледи каршына килеп басты да,— араларында өстәл генә калды,— битендәге маскасын салды.

Бернинди хис-тойгы белгертмәгән тыныч-сабыр, боздай салкын ак чырайлы, кара сакал-бакенбардлы бу кешегә миледи коты оча-оча беравык карап торды да кинәт сикереп торып стенага таба чигенде.

— Юк, юк! — диде.— Юк! Әдәми зат түгел бу! Ул түгел бу!.. Коткарыгыз! Коткарыгыз! — дип карлыккан бер тавыш белән кычкырып җибәрде дә стенага таба борылып, аны этеп, чыгып качмакчы булгандай итте.

Бу тамашаның барлык шаһитлары берьюлы:

— Сез кем буласыз соң? — дип сорадылар.

— Менә бу хатыннан сорагыз. Күреп торасыз бит: мине таныды ул,— диде кызыл плащлы кеше.

Миледи, куркуыннан шашар дәрәҗәгә җитеп, егылып китмәс өчен куллары белән стенага тотына-тотына:

— Лилль палачы ул! Лилль палачы! — дип кычкырды.

Шунда бөтенесе дә арткарак чигенделәр һәм кызыл плащлы кеше бүлмә уртасында бер ялгызы калды.

Кабахәт, явыз хатын, тезләренә чүгеп:

— Ай, зинһар кызганыгыз, кызганыгыз, кичерегез мине! — дип кычкырып ялварырга кереште.

Ят кеше бүлмәдә тынлык урнашканын көтеп басып тора бирде.

— Мине таныды дип әйттем бит сезгә! Әйе, мин Лилль каласының палачы,— диде ул,— минем тормышым болай булды,— дип сөйләргә җыенды.

Бөтенесе, бу кешенең нәрсә әйтәсен борчылып көткән хәлдә, аңа текәлеп карап тора башладылар.

— Бу яшь хатын заманында шундый ук чибәр яшь кенә бер кыз иде. Ул Таплемардагы бенедиктчылар монастыреның бер монахинясы иде. Шул монастырьның чиркәвендә саф күңелле, бик диндар бер яшь рухани гыйбадәт кылдыра иде. Бу хатын аның күңелен аздырырга ният итеп, рухани егетне изге юлыннан яздыра: чөнки ул изге әүлияне дә аздыра, юлдан яздыра ала.

Монахлык вәгъдәсе изге ул, аны бозарга ярамый; аларның бу мөнәсәбәтләре озын гомерле була алмый, үзләрен кайчан да бер харап итәчәк иде... Монах кыз сөйгән егетен бу тирәдән ераграк китәргә үгетли, әмма моннан Франциянең икенче ягына китеп, үзләрен беркем белмәгән тыныч җиргә барып урнашыр өчен, акча кирәк була, ә боларның берсенең дә акчасы юк. Шуннан инде рухани егет изге савытларны урлап сата, әмма гашыйкларны икәү китәргә җыенган чакларында гына эләктереп алалар.

Бер атнадан соң бу хатын, төрмә башлыгының малаен алдап, төрмәдән кача. Рухани егетне, кул-аякларын богаулап һәм тәненә хурлык тамгасы сугып, ун елга төрмәгә хөкем итәләр. Шушы хатын әйткәнчә, мин Лилль каласының палачы идем, минем бурычым хөкем ителгән кешегә хурлык тамгасы салу иде, ә теге рухани егет минем туганым иде, әфәнделәрем!

Шул чагында мин туганымны аздырып харап иткән, аның ярдәмчесе генә булып калмаган, аны җинаятьле эшкә этәргән бу хатын ким дигәндә туганым белән уртак җәза алыр дип ант иттем. Мин аның кайда качып ятуын сизенеп, эзенә төштем, аннары барып тоттым да, аяк-кулларын бәйләп, туганыма салган шикелле, моның да тәненә тамга салдым.

Мин Лилльгә кайтканның икенче көнендә минем туганым да төрмәдән качкан иде. Мине аңа ярдәм иткән дип гаепләделәр, качкан җинаятьче үзе төрмәгә кире кайтканчы, мине төрмәгә ябарга дип хөкем чыгардылар. Бичара туганым бу хөкем карарын белми. Ул яңадан бу хатын янына бара, шуннан алар икәү Беррига качып китәләр, шунда аңа кечерәк бер приход бирәләр. Бу хатын үзен аның сеңлесе итеп күрсәтә.

Приход чиркәве урнашкан җирнең хуҗасы, бер вельможа, бу ялган сеңелне күреп, шуңа гашыйк була, бик гашыйк булып, аны үзенең хатыны булырга өнди. Шуннан инде бу хатын үзе-

нең юлдан яздырган кешесен харап итәсе кешесе хакына ташлый да графиня де ла Фер булып китә...

Бөтенесе дә чын исеме граф де ла Фер булган Атоска (аның чын исеме граф де ла Фер иде бит) һәм шунда Атос башын кагып кына палач әйткәннәрнең дөрес икәнлеген раслады.

Палач сөйләвендә дәвам итте:

— Шуннан соң инде минем бичара туганым, акылларын җуяр дәрәҗәдә өметсезлеккә төшеп, бу хатын бозып киткән тормышыннан котылырга теләп,— чөнки аның абруй-дәрәҗәсе дә, бәхет-шатлыгы да калмаган,— Лилльгә кире кайта; минем аның урынына төрмәдә утырганымны белгәч, ул үз иреге белән төрмәгә кире бара да шул кичне үк зинданының төннек рәшәткәсенә асылынып үлә. Хәер, шунысын да әйтеп китим: мине хөкем итүчеләр үз сүзләрендә тордылар. Асылынып үлүченең кем икәнлеге ачыклангач, мине ирекка чыгардылар.

Бу хатынны мин әнә шул җинаяте өчен гаеплим, әнә шул җинаяте өчен аның тәненә хурлык тамгасы салынды!

— Д'Артаньян әфәнде, бу хатынга нинди җәза бирүне сорыйсыз сез? — диде Атос.

— Үлем җәзасы,— диде д'Артаньян.

— Милорд Винтер, бу хатынга сез нинди җәза бирүне сорыйсыз?

— Үлем җәзасы,— дип җавап бирде лорд Винтер.

— Портос әфәнде белән Арамис әфәнде,— сез бу хатынны хөкем итүчеләр,— сез аңа нинди җәза бирәсез?

Ике мушкетер тонык бер тавыш белән:

— Үлем җәзасы,— дип җавап кайтардылар.

Миледи ачыргаланып кычкырып җибәрде дә тезләнгән хәлендә берничә адым үзен хөкем итүчеләргә таба шуышты.

Атос кулын күтәрде.

— Шарлотта Баксон, графиня де ла Фер, миледи Винтер,— дип эндәште ул,— сез кылган явызлыкларны күреп, җирдәге кешеләрнең дә, күктәге ходайның да инде сабырлыклары төкәнде. Берәр белгән догагыз булса, укыгыз, чөнки үлемгә хөкем ителеп, җан тәслим кылачаксыз.

Үзенә бернинди өмет калдырмый торган бу сүзне ишеткәч, миледи торып туп-туры басты да нәрсәдер әйтмәкче булды, ләкин шунда хәлсезләнеп китте; ул бары тик ниндидер рәхимсез, каты бер кулның, аның чәченнән тотып алып, тәкъдир кешене йөрткән кебек, котылгысыз бер хәлдә алып чыгып киткәнен генә тойды. Миледи хәтта карышып та маташмады.

Лорд Винтер, д'Артаньян, Атос, Портос һәм Арамис аның артыннан чыктылар. Хезмәтчеләр хуҗа әфәнделәренә ияделәр; тәрәзәсе ватылган, ишеге каерып ачылган буш бүлмәдә өстәл өстендә, кайгы төсе биреп, лампа уты гына тотәп калды.

## XXXVI

## ҖӘЗАЛАУ

Төн урталары иде; Армантьер каласы артыннан, соңгы яшен ажаганнары шәүләсеннән кызарып-кызарып, кutek ай калкып килә, аның тонык яктысында йорт шәүләләре һәм челтәрле биек колокольняның манарасы караеп күренә. Алда, эрегән кургаш ташкыны төсле суы белән, Лис елгасы агып ята, елга аръягында төркем-төркем агач ябалдашлары күренә — дөм-караңгы төн уртасын кичке эңгер чакларына охшатып күк йөзеннән актарылган зур-зур алсу-кызгылт болытлар яктысында чекрәеп-караеп күренә иде ул агач ябалдашлары. Сул тарафта ташландык иске бер җил тегермәне калкып тора, аратирә шуның хәрабәләре арасыннан әче тавыш белән ябалак кычкырганы ишетелеп куя. Хөкемчеләр атлаган юлның якягындагы үзәндә анда-санда караңгылык эченнән юан төпле тәбәнәк кенә агачлар калкып килеп чыга да шулар бу шомлы сәгатьтә, җиргә чүгәләп, кешеләрне сагалап торучы котсыз бер кәрләләргә охшап китәләр иде.

Вакыт-вакыт зур яшен уты бөтен күк читен яктыртып җибәрә дә, караеп күренгән агач ябалдашлары өстендә елан төсле бөтерелеп алып, иләмсез зур кәкре хәнҗәр сыман, күк белән суны урталай ярып төшә иде. Бөркү һавада аз гына җил искәне дә сизелми. Бөтен табигатьне үле бер тынлык баскан, әле генә яңгыр явып узганга, җир юеш, аяк асты тайгак, үләннәрдән тәмле исләр тарала башлаган иде.

Гримо белән Мушкетон алдан, миледины кулларыннан тотып алып баралар; алар артыннан палач атлый, лорд Винтер, д'Артаньян, Атос, Портос һәм Арамис исә палач артыннан ияргәннәр.

Планше белән Базен иң арттан киләләр иде.

Хезмәтчеләр миледины елга буена алып баралар. Миледи берни эндәшмәсә дә, күзләре, аларның әле берсенә, әле икенчесенә ялварулы-инәнүле бер төс белән карап, әйтеп биргесез мәгънә белдерә иде.

Миледи, башкалардан берничә адым алдарак баруыннан файдаланып, хезмәтчеләргә:

— Миңа качарга булышсагыз, һәркайсыгызга меңәр пистоль акча бирәм,— дип әйтеп карады,— әмма мине хуҗа әфәнделәрегез кулына тапшырсагыз, белеп торыгыз: бу тирәдә минем үч алучы кешеләрем бар, минем җаным өчен бик кыйммәт түләтәчәк алар сездән,— диде.

Гримо икеләнә калды. Мушкетон калтырана ук башлады.

Атос милединың сөйләшкәнен ишетте дә тиз генә болар янына йөгереп килде, аның артыннан лорд Винтер да килеп җитте.

— Бу хезмәтчеләргезне алыгыз, миледи аларга нидер әйтте, боларга ышанып булмый хәзер,— диде ул.

Атос Планше белән Базенны чакырып китергәч, алар Гримо белән Мушкетонны алмаштырдылар.

Барысы да елга буена килеп җиткәч, палач, миледи янына килеп, аның аяк-кулларын бәйләде.

Шул чагында инде миледи телгә килде:

— Куркак җаннар сез, кеше үтерергә җыенучы мескен адәмнәр, бер хатын-кызны үтерер өчен унике җыелгансыз. Сак булыгыз! Мена хәзер килеп мине коткармасалар, минем үчемне кайтармый калмаячаклар сездән! — дип кычкырды.

— Хатын-кыз түгел сез, кеше түгел сез, җәһәннәмнән килгән иблис сез, шуңа күрә без сезне анда кире кайтарабыз! — диде Атос, салкын гына.

— Ай мәрхәмәтле әфәнделәр! Белеп торыгыз: минем чәч бөртегемә генә кагылган кеше дә, үз нәүбәтендә, кеше үтерүче булачак,— диде миледи.

Кызыл плащлы кеше, киң йөзле кылычына суккалап:

— Палач, җан кыйса да, кеше үтерүче түгел, ханым. Ул нибары соңгы хөкемче генә. Күршеләребез немецләр әйтмешли, Nachrichter,— диде бу сүзгә каршы.

Палач, шулай ди-ди, милединың аяк-кулларын да бәйләргә керешкәнлектән, миледи бик яман бер тавыш белән кычкырып җибәрде — аның бу авазы караңгы бер тынлыкта бик сәер һәм шомлы булып яңгырады да урман эченә китеп тынып калды.

— Әгәр гаепле булсам, җинаять кылган булсам, судка илтегез мине. Мине хөкем итеп, җәза бирергә сез судья түгел бит, — диде миледи үкереп.

— Мин сезгә Тайбернны тәкъдим иткән идем бит, нигә анда китәргә теләмәдегез? — диде лорд Винтер.

— Чөнки минем үләсем килми! — диде миледи, палач кулыннан ычкынырга тырышып.— Мин бик яшь әле, шуңа үләсем килми!

— Бетюнда сез агулап үтергән хатын сездән дә яшьрәк иде, ханым, шулай да үлде ул,— диде д'Артаньян.

— Мин монастырьга китәм, монахиня булам...— дип сөйләнде миледи.

— Сез монастырьда булдыгыз инде, минем туганымны харап итү өчен качып киттегез аннан,— диде палач.

Миледи коты чыгып кычкырып куйды да җиргә тезләнде.

Палач аны, күтәреп алып, көймәгә илтмәкче булды.

— Ай аллам! Ай аллам! Әллә мине батырырга җыенасызмы?! — дип кычкырды миледи.

Ачыргаланып кычкырган бу аваз шул кадәр дә җанга тия, бәгырьне телгәли иде — моңарчы миледига карата иң мәрхәмәтсез булган д'Артаньян түзмәде — янындагы агач төпсәсенә чүгәләп, башын инде дә куллары белән колакларын томалады; тик, шулай итүенә дә карамастан, милединың имәнеч тавышы белән куркыту-янаулары барыбер ишетелде аңа.

Д'Артаньян арада иң яше иде, шуңа күрә аның түземе җитмәде.

— Мондый коточкыч хәлне карап тора алмыйм мин! Бу хатынның шушы рәвешле үлүенә юл куя алмыйм! — диде.

Миледи аның бу сүзләрен ишетеп калды, күңелендә өмет чаткысы уянды.

— Д'Артаньян! Д'Артаньян! Исеңә төшер: мин бит сине яраткан идем! — дип кычкырды ул.

Егет торып басты да миледига таба атлады.

Ләкин шунда Атос, кылычын чыгарып, д'Артаньянның юлына аркылы төште.

— Д'Артаньян, тагын бер генә адым атласагыз да, кылычка кылыч киләчәкбез,— диде ул.

Д'Артаньян, җиргә чүгеп, дога укырга кереште.

— Я, палач, эшеңне башкар,— диде Атос.

— Башкарабыз, галиҗәнап, чөнки мин рәхимле католик, бу хатынга карата вазифамны үтәп, гаделлек эшлим дип ышанам,— диде палач.

— Яхшы.

Атос миледи янына килде.

— Мин сезнең үземә карата кылган барлык явызлыкларыгызны кичерәм. Җимерелгән киләчәгем өчен, югалган абруем, мәсхәрә ителгән мәхәббәтем өчен, сезнең аркада өметсезлеккә төшеп, мәңгегә биртелеп калган җаным өчен кичерәм мин сезне. Бәхиллектә үлегез! — диде Атос.

Лорд Винтер да миледи янына килде.

— Туганымны агулаган, галиҗәнап лорд Бекингэмны үтергәнегез өчен кичерәм мин сезне, бичара Фельтонның үлеме өчен дә кичерәм, мине үтерергә җыенганыгыз өчен дә кичерәм. Бәхиллектә үлегез!

— Ә мин, ханым,— диде д'Артаньян,— дворян кешегә лаек булмаганча, сезне алдап ачуыгызны китергәнем өчен гафу үтенәм. Үзем мин, бичара сөйгәнемне үтергәнегез һәм рәхимсез үч алганыгыз өчен сезне кичерәм. Мин сезне бәхиллим, язмышыгыз өчен кайгырам. Бәхиллектә үлегез!

— I am lost! * I must die! ** — дип миледи инглизчә пышылдап кына әйтеп куйды.

Һәм бернинди ярдәмнән башка гына аягына торып басты да ут кебек көйрәгән үткен бер караш белән бөтен тирә-ягына күз йөртеп чыкты.

Тик бер нәрсә дә күрмәде.

Тирә-ягына колак салып карады, тик берни ишетмәде.

Аның янында дошманнарыннан гайре беркеме дә юк иде шул.

— Кайда үләм мин? — дип сорады миледи.

---

* Беттем мин.

** Мин үләргә тиешмен.

— Теге якта,— диде палач.

Шулай дип, ул миледины көймәгә утыртты, һәм, бер аягы белән көймәгә атлагач, Атос аңа янчык белән алтын сузды.

— Мәгез, хөкем карарын җиренә җиткергән өчен булыр, безнең судьялар буларак эш иткәнебезне белеп торсыннар,— диде ул.

— Яхшы,— диде палач.— Ә хәзер инде бу хатын минем кәсеп итүемне түгел, бәлки бурычымны башкарганымны да белеп торсын.

Палач шулай диде дә алтынны суга ташлады.

Җинаятьче хатын белән палач утырган көймә Лис елгасының сул як ярына таба йөзеп китте. Башкалары уң як ярда калып, җиргә тезләнделәр.

Көймә, елга турысындагы аксыл болыт шәүләсеннән яктыра төшеп, паром йөри торган аркан буйлап әкрен генә йөзеп китте.

Аның аргы якка җитеп туктаганы күренде; комач кызыл күк йөзе җирлегендә палач белән милединың сыннары кап-кара шәүләләр сыман күренә иде.

Елганы кичкән чакта миледи үзенең аякларын бәйләгән бауны чишеп өлгергән иде; көймә ярга җитү белән, миледи ялт кына җиргә сикереп төште дә йөгерә дә башлады.

Әмма аяк асты бик юеш иде; миледи яр өстенә менеп җиткәч, аягы таеп китте дә җиргә тезләнде.

Күңеленә килгән хорафат вәсвәсәсе аны ихтыярсыз итте; тәңрем мине ярдәменнән ташлады дип уйлап, миледи башын игән, кулларын кушырган килеш, шул хәлендә торып калды.

Шул чагында икенче як ярдан палачның иплэп кенә ике кулын да күтәргәнен күрделәр; ай яктысында киң кылычының йөзе ялтырап китте дә куллары аска төште; «чаж!» итеп кылыч сызгырганы һәм ачыргаланып кычкырып җибәргән тавыш ишетелде дә башсыз калган гәүдә җиргә савылып төште.

Палач кызыл плащын, өстеннән салып, җиргә җәйде, шуның өстенә үле гәүдә белән башны салып, плащны төреп бәйләде дә, җилкәсенә күтәреп, яңадан көймәгә керде.

Лис елгасының уртасына җиткәч, көймәне туктатты, төргәкне баш өстенә күтәреп, каты тавыш белән:

— Ходайның хөкеменә тапшырдык! — дип кычкырды да мәетне су төбенә җибәрде.

Өч көннән соң дүрт мушкетер Парижга кайттылар; аларның ял срогы бетмәгән иде әле, шул кичне үк де Тревил әфәнде янына гадәттәгечә визит ясадылар.

— Я, хәлләрегез ничек, әфәнделәр, ялыгызны күңелле үткәрдегезме? — дип сорады алардан батыр капитан.

Атос үзе өчен дә, иптәшләре өчен дә:

— Искиткеч шәп булды! — дип җавап кайтарды.

# СОҢГЫ СҮЗ

Икенче айның алтысы көнне король, Ларошельгә кире киләм дип кардиналга биргән вәгъдәсен үтәп, башкаладан чыгып китте — Бекингэмны үтергәннәр дигән хәбәргә шаккатып, шуның тәэсиреннән ул әле айнып та җитмәгән иде.

Королеваны сөйгән кешесенә куркыныч бар дип кисәтеп куйган булсалар да, Бекингэмның үтерелгәнлеген ишеткәч, аның бу хәлгә ышанасы килмәде; ул хәтта саксызланып:

— Ялган сүз ул! Шушы арада гына ул миңа хат җибәргән иде,— дигән сүз дә ычкындырды.

Шулай да иртәгесе көнне королевага бу коточкыч хәбәрнең дөреслегенә ышанырга туры килде: Ла Порт (Англиядән чыгып китүче башка кешеләр кебек, король Карл I нең боерыгы белән аны да тоткарлап җибәрмичә торганнар иде) Бекингэмның үләре алдыннан королевага җибәргән бүләген алып кайтып тапшырды.

Корольнең шатлыгы бик зур иде, хәер, ул аны яшереп тә маташмады, бу хәбәргә сөенгәнлеген королева алдында хәтта юри сиздерде. Людовик XIII дә, йомшак характерлы кешеләр кебек, олы җанлы кеше түгел иде шул.

Тик озакламый корольнең тагын чырае караңгыланды, тагын эче поша башлады: аның күңелендә сөенеч-шатлык әллә ни озак сакланмый иде шул; лагерьга кире кайткач, яңадан кол хәленә төшәсен ул сизеп тора, шулай да анда кайтырга тиеш иде.

Аның өчен кардинал сихерле бер елан, ә үзе ботактан ботакка очып та еланнан котыла алмаучы бер кош иде.

Шуңа күрә Ларошельгә кире кайту бик күңелсез иде. Бигрәк тә безнең дүрт дуска иптәшләре шаккатты: алар, караңгы бер чырай белән башларын аска иеп, дүртәү янәшә баралар. Тик вакыт-вакыт Атос кына мәһабәт башын күтәреп куя, күзләрендә чаткылар кабынып китә, иреннәре ачылып көлгән сыман елмайгандай итә, аннары инде яңадан, иптәшләре кебек, уйчанланып кала иде.

Берәр калага җитеп, корольне төн куна торган йортына озатып куйгач та, дуслар шундук я үз торакларына кайталар, я кала читендәге берәр кабакка китәләр, ләкин алар анда шакмак та уйнамыйлар, шәраб та эчмиләр, бары тик, берәр кеше тыңлап тормыймы дип як-якларына карана-карана, шыпырт кына үзара сөйләшәләр.

Бер көнне, король бераз ауда йөреп алырга дип юлда ялга туктагач, дүрт дус исә, аучыларга кушылмыйча, гадәтләренчә юл буендагы трактирга баргач, Ларошельдән җан фәрманга ат чаптырып килгән берәү, берәр стакан шәраб эчмәкче булып, атын шул трактирның ишеге төбенә китереп туктатты да дүрт мушкетер утырган бүлмәгә күз салып:

— Әй, д'Артаньян әфәнде! Сезне күрәм түгелме мин анда? — дип кычкырды.

Д'Артаньян, башын күтәреп карау белән, шатлыгыннан кычкырып җибәрде. Егет үзенең өрәге дип санаган, Мёнгта, Каберчеләр урамында һәм Арраста очраткан теге ят кеше иде бу.

Д'Артаньян кылычын суырып чыгарды да ишеккә ташланды.

Әмма ят кеше бу юлы качмады, атыннан сикереп төште дә үзе д'Артаньянга каршы килә башлады.

— Әһә, хәзер менә таптым инде мин сезне, мөхтәрәм әфәндем! Бу юлы инде миннән качып китә алмассыз,— диде егет.

— Минем бер дә андый исәбем юк, бу юлы мин үзем сезне эзләп килдем. Король исеменнән, мин сезне кулга алам. Кылычыгызны миңа тапшыруыгызны сорыйм, хөрмәтле әфәндем. Карышырга маташмагыз: кисәтеп куям, сезнең гомерегез турында бара сүз.

Д'Артаньян кылычын, аңа бирмичә, аска төшереп:

— Ә сез кем буласыз? — дип сорады.

— Мин — кавалер де Рошфор, кардинал де Ришелье җәнапларының атбагары. Миңа сезне кардинал хәзрәтләре янына китерергә дигән боерык бирелде,— диде ят кеше.

Шунда Атос та, якынрак килеп, сүзгә кушылды:

— Без үзебез дә кардинал хәзрәтләре янына кайтып киләбез, кавалер әфәнде; сез, әлбәттә, д'Артаньян әфәнденең туптуры Ларошельгә барам дигән сүзенә ышанасыз.

— Мин аны сакчылар кулына тапшырып, алар аны лагерьга алып кайтырга тиешләр.

— Без үзебез аңа сакчы булырбыз, мөхтәрәм әфәнде, сезгә дворян буларак сүз бирәм. Шулай ук сезгә д'Артаньян әфәнде бездән башка китмәячәк дип тә сүз бирәм,— дип өстәде Атос, кашларын җыерып.

Кавалер де Рошфор, борылып карап, Портос белән Арамисның аның белән ишек арасына килеп басканлыкларын күрде һәм үзенең бөтенләе белән шушы дүрт кеше кулында икәнлеген аңлап алды.

— Әфәнделәр,— дип эндәште ул аннары,— әгәр д'Артаньян әфәнде кылычын миңа тапшырып, сезнең кебек сүз дә бирсә, д'Артаньян әфәндене кардинал җәнаплары ставкасына илтәбез дигән вәгъдәгезгә риза булам мин.

— Мәгез, мөхтәрәм әфәнде,— диде д'Артаньян.

— Болай булуы минем өчен бик җайлы килеп чыкты әле, минем арырак китәсем бар иде,— диде Рошфор.

— Миледи белән очрашу өчен булса, файдасы юк, сез инде аны бүтән күрмәячәксез! — дип куйды Атос салкын гына.

Рошфор әсәрләнебрәк:

— Ә нәрсә булды соң аңа? — дип сорады.

— Менә лагерьга кайткач белерсез.

Рошфор чак кына уйланып торды да, бу җирдән кардинал корольне каршылыйсы төшкә, ягъни Сюржерга чаклы нибары бер генә көнлек юл булганлыктан, Атосның киңәшен тотып, мушкетерлар белән бергә шунда кайтырга карар итте.

Өстәвенә ул үзе кайтканда кулга алынучы егеткә күз-колак булып та кайта иде.

Шулай итеп, барысы бергә тагын юлга кузгалдылар.

Иртәгесе көнне төштән соң сәгать өчтә Сюржерга килеп җиттеләр. Кардинал шунда Людовик XIII не көтеп тора иде. Министр белән король үзара бик күп мактау сүзләре әйтештеләр, бер-берен Франциягә каршы бөтен Европаны күтәргән көчле дошманнан коткарган шатлыклы хәл белән тәбрик иттеләр. Шуннан соң инде кардинал, король белән саубуллашып, аны иртәгә өр-яңадан өелгән буаны килеп карарга чакырды — Рошфор аңа д'Артаньянның кулга алынганлыгын әйтеп куйганлыктан, кардиналның тизрәк мушкетер егетне күрәсе килә иде.

Кичен де ла Пьер күпере төбендәге ставкасына кайтуга, кардинал үзе урнашкан йортның ишеге төбендә кылычсыз д'Артаньян белән кораллы өч мушкетерны күрде.

Бу юлы, көч үз ягында булгач, кардинал аларга кырыс-усал бер төс белән карады да кулын изәп һәм карашы белән ымлап кына д'Артаньянга үз артыннан ияреригә кушты.

Д'Артаньян карышмады.

Атос, кардинал да ишетсен дигәндәй, катырак кычкырып:

— Без сине көтеп торабыз, д'Артаньян,— диде.

Кардинал хәзрәтләре, кашларын җыерып, туктала калды, аннары, бер сүз эндәшмәстән, йортка кереп китте.

Д'Артаньян да кардинал артыннан йортка керде, иптәшләре исә, аны саклап, тышта калдылар.

Кардинал хәзрәтләре туп-туры үзенә кабинет булып хезмәт иткән бүлмәгә узды да Рошфорга, ишарәләп кенә, мушкетер егетне үзе янына кертергә кушты.

Рошфор аның боерыгын үтәү белән чыгып та китте.

Д'Артаньян кардинал белән икәү генә калды. Бу инде аның Ришелье белән икенче тапкыр күрешүе, мушкетер егет азактан үзе әйткәнчә, моның соңгы күрешүе буласына ул тәгаен ышанган иде.

Ришелье каминга сөялгән килеш басып тора бирде; д'Артаньян белән аның арасында өстәл генә бар иде.

— Хөрмәтле әфәндем, сез минем боерык белән кулга алындыгыз,— дип сүзгә башлады кардинал.

— Миңа аны әйттеләр, галиҗәнап.

— Ә ни өчен икәнен беләсезме?

— Юк, белмим, галиҗәнап, чөнки мине кулга алдырырдай бердәнбер сәбәп сез галиҗәнап хәзрәтләренә мәгълүм түгел әле.

Ришелье егеткә текәлеп карады.

— Шулаймыни! Ни дигән сүз соң бу?

— Әгәр алдан сез, галиҗәнап, минем нинди гаебем барлыгын әйтсәгез, шуннан соң мин үземнең чынлыктаниләр кылганымны сөйләп бирер идем.

— Сезнеке нише гаеп өчен, хөрмәтле әфәндем, сездән дәрәҗәлерәк кешеләрнең дә башын кистеләр! — дип җавап кайтарды Ришелье.

— Нинди гаеп соң ул, галиҗәнап? — дип сорады д'Артаньян, кардинал хәтле кардиналны гаҗәпкә калдырырлык бер сабырлык белән.

— Сезнең гаебегез шул: сез дәүләтебезнең дошманнары белән хат алышкансыз, сез дәүләт серләрен сорашып белгәнсез, үзегезнең хәрби башлыгыгызның планнарын җимерергә маташкансыз.

— Шулай дип кем гаепли мине, галиҗәнап? — диде д'Артаньян, моның миледи эше икәнлегенә төшенеп.— Дәүләтебезнең гадел хөкеме белән тәненә хурлык тамгасы сугылган хатын, Франциядә бер кешегә, ә Англиядә икенче кешегә иргә чыккан хатын, икенче ирен агулап үтергән һәм мине дә агуларга маташкан хатын гаепли мине?

— Ни сөйлисез сез, хөрмәтле әфәндем! Нинди хатынны әйтәсез сез? — дип гаҗәпләнеп әйтеп куйды кардинал.

— Миледи Винтерны әйтәм,— диде д'Артаньян.— Әйе, миледи Винтерны әйтәм, сез ул хатынга ышанып эш иткәндә аның барлык җинаятьләре дә сез галиҗәнапка мәгълүм булмаган, күрәсең.

— Әгәр миледи Винтер сез әйткән җинаятьләрне эшләгән булса, тиешле җәзасын алыр ул, хөрмәтле әфәндем.

— Тиешле җәзасын алды инде ул, галиҗәнап.

— Ә кем аңа җәза бирде?

— Без бирдек.

— Төрмәдәме ул?

— Үлде ул.

— Үлде?! — дип куйды кардинал шаккатып.— Үлде?! Дөрес әйтәсезме?

— Мине өч тапкыр үтерергә маташты ул, мин аны кичерә килдем, шуннан соң ул минем сөйгәнемне агулап үтерде. Аннары инде мин дусларым белән аны эзләп таптык та үлем җәзасына хөкем иттек.

Д'Артаньян Бетюндагы кармелиткалар монастыренда Бонасье ханымның агулап үтерелүе, аулак өйдәге хөкем, Лис елгасы буенда үлем җәзасының җиренә җиткерелүе турында сөйләп бирде.

Кардиналның бөтен тәне тетрәнеп-калтыранып китте, ә мондый хәлне ул бик сирәк кичерә иде.

Әмма шунда кардиналның караңгы чырае, телдән әйтелмәгән ниндидер уй-фикер тәэсир иткән сыман, әкренләп яктыра башлады да ахырда бөтенләй тынычланып калды.

— Димәк, сез җәза бирергә хокукы булмый торып та җәзалаучы кешеләрнең адәм җаны кыючы икәнлекләрен уйлап тормастан, үзегезгә хакимлек хокукы алгансыз! — диде ул, усал сүзләренә туры килми торган юаш бер тавыш белән.

— Галиҗэнап, ант итеп әйтәм: минем сезнең алдыгызда тамчы да аклану теләгем булмады. Сез галиҗэнап хәзрәтләре биргән җәзаны алырга мин әзермен. Мин алай, үлүдән куркып, җаным өчен дер калтырап яшәмим.

Кардинал, ягымлы диярлек бер тавыш белән:

— Әйе, мин сезнең батыр кеше икәнегезне беләм. Шуңа күрә сезгә алдан ук әйтеп куя алам: сезне хөкем итәчәкләр, хәтта җәза да бирәчәкләр.

— Башка бер кеше булса, сез галиҗэнап хәзрәтләренә әйтер иде: минем гаебемне гафу иткән кәгазегез минем кесәмдә, дияр иде, тик мин сезгә шулай дип кенә әйтәм: әмерегезне бирегез, галиҗэнап, барысына да әзер мин.

— Гаебегезне гафу иткән кәгазь? — диде Ришелье, гаҗәпләнеп.

— Әйе, галиҗэнап,— дип җавап бирде д'Артаньян.

— Ә кем кул куйган соң аңа? Корольме?

Бу сүзне кардинал аеруча бер кимсетү төсмере белән әйтте.

— Түгел, сез галиҗэнап куйгансыз.

— Мин? Нәрсә сез, әллә акылыгыздан яздыгызмы?

— Сез инде үз кулыгызны таныйсыздыр, галиҗэнап.

Шулай дигәч, д'Артаньян Атос, миледидан талап алып, дустына, саклык язуы булсын, дип тапшырган кыйммәтле кәгазьне кесәсеннән чыгарып бирде.

Кардинал хәзрәтләре, кәгазьне алып, һәр сүзгә басым ясыйясый, ашыкмый гына укырга керешге:

«Шушы кәгазьне күрсәтүче кешенең кылган гамәлләре, минем боерык буенча, дәүләт файдасына эшләнде.

1627 елның 9 декабре.

*Ришелье*».

Шул ике юлны укыгач, тирән уйга калды, ләкин кәгазьне д'Артаньянга кире кайтармады.

«Миңа нинди үлем җәзасы бирү турында уйлана. Ант әгәр, чын дворянның ничек үлгәнен күрсәтәм мин аңа!» — диде д'Артаньян күңеленнән.

Мушкетер егетнең халәте рухияте бик шәп булып, теге дөньяга каһарманнарча китеп барырга әзерләнеп тора иде.

Ришелье, уйлана-уйлана, кулындагы кәгазьне бер бөтерде, бер сүтте. Ахырда башын күтәреп, бөркетнекедәй үткен карашын д'Артаньянның риясыз, акыллы, чибәр йөзенә текәде, егетнең әле һаман да күз яше эзләре бетмәгән чыраеннан аның соңгы айда кичергән барлык газап-михнәтләрен аңлады, нибары егерме бер генә яшендәге бу егетнең бик өметле булуын, зирәк акыллы хаким аның көч-гайрәте, акылы һәм батырлыгыннан бик уңышлы файдаланачагын өченчеме, дүртенчеме тапкыр уйлады.

Икенчедән, милединың җинаятьләре, көч-куәте һәм иблиснеке кебек зиһен-сәләте кардиналның йөрәгенә курку да салгалый иде. Шул хәтәр булышчысыннан бөтенләйгә котылдым дип уйлап, ул эченнән генә сөенеп тә куйды.

Д'Артаньян олы җанлылык күрсәтеп кире кайтарган кәгазьне кардинал ашыкмый гына, җайлап кына ертып ташлады.

«Беттем!» — дип уйлады д'Артаньян.

«И ходаем, ни язган булсаң — шул булыр»,— дигән сыман, кардинал алдында башын иеп басып тора бирде.

Кардинал өстәл янына килде, урындыкка утырмыйча гына, өчтән ике өлеше тутырылган пергаментка берничә юл өстәп язды да шуңа печәтен басты.

«Миңа хөкем карары инде бу, кардинал мине Бастилиягә ябып ялыктырудан да, озаклап суд тикшерүеннән дә коткара. Аның тарафыннан бик зур илтифат инде бу»,— дип уйланды д'Артаньян.

— Мәгез! Мин сездән бер таныклык кәгазе алган идем, аның урынына икенчене бирәм. Бу грамотага исемегез куелмаган, үзегез язарсыз,— диде кардинал егеткә.

Д'Артаньян шикләнә-шикләнә генә кәгазьне алды да күз салды.

Мушкетерлар лейтенанты чины бирү турындагы указ иде бу.

Д'Артаньян кардиналның аягына егылды.

— Галиҗәнап, минем гомерем үлгәнче сезнең ихтыярыгызда, моннан ары сез хуҗа аңа. Тик шулай да мин сезнең бу кадәр яхшылыгыгызга лаек түгелмен: минем күбрәк хезмәт күрсәткән лаеклырак өч дустым бар әле...

Кардинал, аны сүзеннән бүлдереп:

— Бик шәп егет сез, д'Артаньян,— диде, бу баш бирмәс егетне буйсындыра алуыннан бик канәгать булып, дусларча аны җилкәсеннән чәбәкләп алды.— Үзегез теләгәнчә файдаланыгыз бу грамотадан. Тик шуны онытмагыз: исемегезне куймасам да, мин аны сезгә тапшырам.

— Мин моны гомеремдә дә онытмам. Моңа бер дә шикләнмәгез, галиҗәнап,— диде д'Артаньян.

Кардинал борылды да каты гына итеп:

— Рошфор! — дип эндәште.

Кавалер ишек артында гына торган, күрәсең,— шундук килеп тә керде.

— Рошфор,— диде кардинал,— сезнең алдыгызда д'Артаньян әфәнде басып тора, мин аны дустым итеп алам, шуның өчен икегез дә үбешегез һәм, башларыгыз исән булсын, дисәгез, үзегезне акыллы тотыгыз.

Рошфор белән д'Артаньян, иреннәрен чак кына тидереп, үбешеп алдылар: кардинал, шунда уяу күзләрен текәп, аларга карап торды.

Шуннан соң алар икәү бүлмәдән чыктылар.

— Без тагын күрешербез әле, шулаймы, хөрмәтле әфәндем?

— Кайчан телисез — шунда,— диде д'Артаньян.

— Җае бик тиз чыгар,— дип җавап бирде Рошфор.

Ришелье, ишекне ачып:

— Нәрсә? — дип сорады.

Тегеләр, бер-берсенә елмаешып, кул кысыштылар да кардинал хәзрәтләренә баш иделәр.

— Безнең инде түземебез бетеп бара иде,— диде Атос.

— Менә мин исән-сау, дусларым! Мин азат кына да түгел, кардинал хәзрәтләренең яхшылыгын да күрдем,— дип җавап бирде д'Артаньян.

— Безгә барысын да сөйләрсездер бит?

— Бүген кич белән үк сөйлим.

Чыннан да, д'Артаньян шул кичне үк Атос янына китте. Ул килеп кергәндә, Атос һәр кичтәге гадәтенчә испан шәрабы эчеп утыра иде.

Д'Артаньян аңа кардинал белән үзе арасында булган хәлне сөйләп бирде дә кесәсеннән теге грамотаны чыгарып:

— Мәгез, Атос дус, бу сезгә тиешле,— диде.

Атос бик матур, ягымлы елмаюы белән елмаеп кына куйды.

— Дустым, Атос өчен бу артык күп, граф де ла Фер өчен исә бик аз булыр. Бу грамотаны сез үзегезгә калдырыгыз, ул — сезнеке. Бик кыйммәт түләп алдыгыз шул сез аны,— диде.

Д'Артаньян, Атос яныннан чыгып, Портос бүлмәсенә барып керде.

Портос көзге каршына баскан: бер дигән чигүле камзул киеп, үз-үзенә сокланып карап тора иде.

— Ә! Сез икәнсез, кадерле дус! — диде ул, д'Артаньянны сәламләп.— Ничек уйлыйсыз: килешәме бу кием миңа?

— Бик килешә, тик мин сезгә икенче бер кием тәкъдим итмәкче идем, анысы тагын да килешәрәк төшәр,— диде д'Артаньян.

— Нинди кием ул?

— Мушкетерлар лейтенанты мундиры.

Д'Артаньян Портоска да үзенең кардинал белән күрешүен сөйләп бирде һәм грамотаны кесәсеннән чыгарып:

— Мәгез, кадерле дус, шушыңа исемегезне язып куегыз да миңа бик әйбәт башлык булыгыз,— диде.

Портос грамотаны карады да, д'Артаньянның гаҗәбенә каршы, кире кайтарды.

— Әйе, минем өчен зур сөенеч булыр иде дә, тик мондый яхшылыктан әллә ни озак файдалана алмас идем шул,— диде.— Без Бетюнга барып кайткан арада минем герцогиняның ире вафат булган, шул сәбәпле мәрхүмнең акча сандыгы минем кулга керергә тора. Мин инде ул тол хатынга өйләнәм, дустым, менә күрәсез, туйга киясе киемемне киеп карадым. Лейтенант исемен үзегезгә калдырыгыз, дустым, үзегезгә калдырыгыз.

Шулай дип, ул грамотаны д'Артаньянга кире кайтарды.

Яшь егетебез Арамис янына китте.

Ул килеп кергәндә, Арамис, аналой каршына тезләнгән хәлдә, ачып салган догалык өстенә иелгән иде.

Д'Артаньян аңа да кардинал белән күрешкәндәниләр булганын сөйләп бирде һәм әлеге грамотаны кесәсеннән өченче тапкыр чыгарып:

— Сез — безнең дустыбыз, якты нурыбыз, күзгә күренми генә саклап йөргән химаячебез — шушы грамотаны үзегезгә алыгыз. Сез зирәк акылыгыз белән, безне уңышка илткән киңәшләрегез белән барыбызга караганда да лаеклырак моңа,— диде.

— Һай, сөекле дустым! — диде Арамис, көрсенеп,— безнең соңгы мажараларыбыз фани дөнья белән гаскәри дәрәҗәдән тәмам күңелемне кайтарды. Бу юлы инде мин катгый бер карарга килдем: бу камау тәмамлану белән лазаристлар берегенә керәм. Бу грамота үзегезгә калсын, д'Артаньян, гаскәри хезмәт сезгә бик килешә, сез бик батыр, бик булдыклы гаскәри башлык булырсыз.

Д'Артаньян, дусларына карата күңелендә туган рәхмәт тойгысыннан күзләре яшьләнеп сөенгән хәлдә, Атос янына кире кайтты. Өлкән дусты әле һаман да өстәл яныннан торып китмәгән, лампа яктысында соңгы стакан малагасын карап утыра иде.

— Менә шул! Алар да алырга риза булмадылар,— диде д'Артаньян.

— Чөнки, дустым, моңа иң лаек кеше сез.

Шулай дип, Атос, кулына каләм алып, грамотага д'Артаньянның исемен язды да егеткә тапшырды.

— Болай булгач, моннан ары минем дусларым булмый инде, кайгылы хатирәләрдән гайре берни калмый!..— диде д'Артаньян. Башын июгә, битләре буйлап ике бөртек күз яше тәгәрәп төште.

— Сез яшь әле, кайгылы хатирәләрегез урынына сөенечләләре дә килер,— диде аңа Атос.

## *ЭПИЛОГ*

Ларошель, Англиянең флоты белән гаскәрләреннән Бекингэм вәгъдә иткән ярдәмне ала алмагач, бер ел камалып торганнан соң, бирелергә мәҗбүр булды. 1628 елның 28 октябрендә капитуляциягә кул куйдылар.

Король Парижга шул ук елның 23 декабрендә кайтып керде. Французларны түгел, бәлки чит дошманнарны җиңеп кайткан кебек, бик зур тантана белән каршы алдылар аны. Король калага Сен-Жак бистәсеннән чәчәкләр һәм яшел ботакларга уралган капкалар аша узып килеп керде.

Д'Артаньян үзенә бирелгән лейтенант дәрәҗәсен кабул итте. Портос гаскәри хезмәттән китеп, алдагы елда Кокнар ханымга өйләнде: төшләренә кергән теге сандыкта сигез мең ливр акча бар иде.

Мушкетон да гомере буе хыялланган зур бәхетенә иреште: искиткеч матур ливрей киеп, алтынлап бизәгән карета артына утырып йөри башлады.

Арамис, Лотарингиягә барып кайтканнан соң, капыл гына юкка чыгып, дусларына хат та язмый башлады. Соңрак де

Шеврез ханым аша шул нәрсә мәгълүм булды — моны ханым үзенең ике-өч сөйгәненә сөйләгән булган — Арамис Нансидагы бер монастырьга монах булып киткән.

Базен послушник булган.

Атос д'Артаньян кул астында 1631 нче елга хәтле мушкетерлыкта хезмәт итте, аннары, Туреньга барып кайтканнан соң, Русильонда беркадәр мирас алдым дигән сылтау белән гаскәри хезмәттән ул да китеп барды.

Аңа ияреп Гримо да китте.

Д'Артаньян Рошфор белән өч тапкыр дуэльдә сугышып, аны өч тапкырында да яралады.

— Дүртенче тапкырында мин сезне үтерермен ахры,— диде егет, Рошфорга торырга булышыйм дип кулын сузып.

— Алайса, шушының белән туктасак, сезнең өчен дә, минем өчен дә хәерлерәк булыр,— диде яраланган Рошфор.— Шайтан алгыры, мин бит сезне үзегез уйлаганнан күбрәк хөрмәт итәм, мин бит беренче тапкыр очрашуыбыздан соң ук сезнең башыгызны кистерә ала идем; кардиналга бер сүз әйтүем дә җитә иде.

Бу юлы инде алар ихлас күңел белән, бернинди риясыз кочаклаштылар.

Планше, Рошфор ярдәме белән, гвардия сержанты дәрәҗәсенә иреште.

Бонасье әфәнде, хатынына ни булганлыгы турында берни белмичә, аның язмышы өчен бер дә борчылмыйча, тыныч кына яшәп ята иде. Көннәрдән бер көнне ул, саксызланып, кардиналга үзенең дөньяда барлыгын искә төшерде; кардинал аңа, моннан ары Бонасье әфәнде бернинди мохтаҗлык күрмәс, мин ул хакта кайгыртырмын, дип әйтергә кушты.

Чыннан да, икенче көнне кичке сәгать сигездә Луврга барам әле дип өеннән чыгып киткән Бонасье әфәнде Каберчеләр урамына инде бүтән әйләнеп кайтмаган: шул хакта белешлеге булган кайбер кешеләрнең әйтүенә караганда, Бонасье әфәнде, кардинал хәзрәтләренең юмартлыгыннан файдаланып, король замокларының берсендә үзенә сыеныр урын тапкан, имеш.

## ЭЧТӘЛЕГЕ


Авторның кереш сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5


### Беренче кисәк


I. Әти кеше д'Артаньян әфәндененң өч бүләге . . . . . . 7
II. Де Тревиль җәнапларының кабулханәсендә . . . . . . 21
III. Аудиенция . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
IV. Атосның кулбашы. Портосның җилкә каешы һәм Арамисның кулъяулыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
V. Король мушкетерлары һәм кардинал хәзрәтләре гвардиячеләре 47
VI. Король хәзрәтләре Людовик Уноченче . . . . . . . . 57
VII. Мушкетерларның өйләрендә чаклары . . . . . . . . . 73
VIII. Король сараендагы интрига . . . . . . . . . . . . 81
IX. Д'Артаньянның характеры ачыла бара . . . . . . . . 89
X. Унҗиденче гасырда тычкан тозагы . . . . . . . . . . 96
XI. Интрига төйнәлә . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
XII. Джордж Виллье, герцог Бекингэмлы . . . . . . . . 119
XIII. Бонасье әфәнде . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
XIV. Мёңгта очраган ят кеше . . . . . . . . . . . . . 135
XV. Гаскәриләр һәм хөкемчеләр . . . . . . . . . . . . 144
XVI. Канцлер Сегьеның кага торган чаңын таба алмавы . . . . 151
XVII. Бонасьелар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
XVIII. Мәгъшуг егет белән ир . . . . . . . . . . . . . . 173
XIX. Кампания планы . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
XX. Сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
XXI. Графиня Винтер . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
XXII. Мерлезон балеты . . . . . . . . . . . . . . . . 205
XXIII. Көрешү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
XXIV. Павильон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
XXV. Портос . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
XXVI. Арамисның диссертациясе . . . . . . . . . . . . 245
XXVII. Атосның хатыны . . . . . . . . . . . . . . . . 260
XXVIII. Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277
XXIX. Гаскәри кирәк-ярак юнәтү . . . . . . . . . . . . 290
XXX. Миледи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298


### Икенче кисәк


I. Инглизләр белән французлар . . . . . . . . . . . . 305
II. Прокурорларда аш мәҗлесе . . . . . . . . . . . . 312
III. Субретка һәм аның байбикәсе . . . . . . . . . . . 320
IV. Арамис белән Портосның гаскәри кирәк-ярак юнәтүләре . . 329
V. Караңгыда бөтен мәче дә соры булып күренә . . . . . . 336

VI. Үч алу хыялы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343
VII. Милединың сере . . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
VIII. Атосның бернинди мәшәкатьсез гаскәри кирәк-ярак табуы . . 356
IX. Төштә генә кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . 364
X. Кардинал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 372
XI. Ларошельне камап торганда . . . . . . . . . . . . 379
XII. Анжуй шәрабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 390
XIII. «Күгәрчен оясы» мәйханәсе . . . . . . . . . . . . 397
XIV. Мич торбасының файдасы . . . . . . . . . . . . . 404
XV. Ир белән хатын очрашуы . . . . . . . . . . . . . 411
XVI. Сен-Жерве бастионы . . . . . . . . . . . . . . . 416
XVII. Мушкетерлар киңәшмәсе . . . . . . . . . . . . . 422
XVIII. Гаилә эше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 438
XIX. Тәкъдир шаяртуы . . . . . . . . . . . . . . . . 450
XX. Кайнага белән киленнең сөйләшүләре . . . . . . . . 457
XXI. Офицер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 463
XXII. Тоткынлыкның беренче көне . . . . . . . . . . . 473
XXIII. Тоткынлыкның икенче көне . . . . . . . . . . . 478
XXIV. Тоткынлыкның өченче көне . . . . . . . . . . . 485
XXV. Тоткынлыкның дүртенче көне . . . . . . . . . . 492
XXVI. Тоткынлыкның бишенче көне . . . . . . . . . . 512
XXVII. Классик трагедиянең сыналган бер ысулы . . . . . . 517
XXVIII. Качу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 524
XXIX. 1628 елның 23 августында Портсмутта булган хәлләр . . . 524
XXX. Франциядә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 534
XXXI. Бетюндагы кармелиткалар монастыре . . . . . . . . 538
XXXII. Ике тәр иблис . . . . . . . . . . . . . . . . . 549
XXXIII. Соңгы тамчы . . . . . . . . . . . . . . . . . 554
XXXIV. Кызыл плащлы кеше . . . . . . . . . . . . . . 566
XXXV. Хөкем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 571
XXXVI. Җәза. ау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 578
Соңгы сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 582
Эпилог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 589

*Дюма Александр*

***ТРИ МУШКЕТЕРА***

(на татарском языке)

Редакторы Т. Нурмөхәммәтов. Художнигы Н. Альмеев. Художество редакторы Г. Трифонов. Техник редакторы Ә. Трофимова. Корректорлары М. Мирсалихова, Р. Хәмидуллина.

ИБ № 1420

Наборга бирелде 24/IV-1979 ел. Басарга кул куелды 17/VIII-1979 ел. Формат 60×90¹/₁₆. Гарнитура литературная. Печать высокая. Типография кәгазе № 2. Учетн.-изд. таб. 40,94. Басма таб. 37,0. Тираж 50.000. Заказ А-307. Бәясе 1 сум 30 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты, Казан, Бауман ур., 19.